

Факил Сафин



# Саташып аткан таң

Роман-трилогия

КАЗАН
ТАТАРСТАН КИТАП НӘШРИЯТЫ
2003

УДК 820/89 (470)
ББК 84 (2Рос=Тат)-44
С24

**Сафин Факил**

С 24 Саташып аткан таң: Роман-трилогия. — Казан: Татар.кит.нәшр., 2003. — 527 б.

Танылган язучы, Г.Исхакый исемендәге премия лауреаты Ф.Сафинның өч китаптан торган «Саташып аткан таң» романы — тарихи әсәр. Тормышта яшәп киткән реаль шәхесләрне әдәби әсәр җирлегендә сурәтләргә алынуы белән автор шактый кыюлык та күрсәтә. Әсәрдәге геройлар язмышы, вакыйгалар агышы, тирән фәлсәфә, җанны кузгатырлык кичерешләр, фактик материаллар белән роман тарих сабагын, ачы хакыйкатьне күрсәтеп бирә.

ISBN 5-298-01347-3
© Татарстан китап нәшрияты, 2003

## «ТАЛАНТЛЫ СИН, КЕШЕ ТУГАНЫМ!»

Минем бәләкәй генә шигъри җаным олы дөньяга Хәсән ага Туфан күзләре белән карый.

Нигәдер, үзем дә аңлата алмыйм, Факил Сафин (Факил Әмәк) турында язарга алынгач та сөекле шагыйрем, аның әдәбият сагында торырга омтылуы хакында уйлап куйдым. Ышанып әйтә алам, Хәсән Туфан Сибгат ага Хәким белән киңәш-табыш итешкәннән соң, әдәбиятка көчле агым булып килеп кергән, татар прозасын олы язмышлы каһарманнар белән баеткан Факил Әмәк иҗатына сөенеп: «Бәрәкәте белән булсын, канәтем!» — дип әйтер иде сыман. Исемнәрдә мондый параллелизм китерүнең сәбәбе дә бар (иҗатта түгел!): әйткәнемчә, Хәсән ага — яраткан шагыйрем, кумирым, Факил Әмәк исә — таланты каршында баш игән прозаигым һәм... горурланырлык якташым. Ул безнең күрше генә авылдан — Әмәкәйдән. Кыскасы, аларның берсе — рухи остазым, икенчесе — рухи туганым!..

* * *

Сафин Факил Миңнемөхәммәт улы 1954 елның 2 гыйнварында Мөслим районының Әмәкәй авылында гаиләдә алтынчы бала булып дөньяга килә. Кечкенәдән әдәбият-сәнгать белән кызыксына. Мондый омтылыш тәрбияләнүдә әтиәнисенең укымышлы, элеккечә әйтсәк, гыйлем ияләре булуы тәэсир иткәндер, күрәсең. Әтисе Миңнемөхәммәт агай инкыйлабка кадәр үк мәдрәсәдә әтрафлы белем ала. Әле атеистик коткы котырган чорда ук, 60 еллар ахырыннан башлап бүгенге көнгә кадәр үз төбәгендә муллалык вазифасын башкарып килә. (Факилнең инсафлы, зыялы шәхес булып формалашуы юктан гына түгел икән ләбаса!) Әнисе дә борынгы муллалар нәселеннән.

Факил Әмәк — һәр әдипкә, катлаулы шәхескә хас булганча, бормалы юллар узган, бай биографияле язучы. (Кем әйтмешли, язучы ул, барыннан да бигрәк, биография!)

Факил Мөслим районы Күбәк урта мәктәбен тәмамлагач, колхозда механизатор булып эшли башлый. Минзәләдә шоферлык һөнәрен үзләштерә. 1972–1974 елларда армия сафларында хезмәт итә: Ерак Көнчыгышта, Кытай чигендә дә иҗат эшен туктатмый. Армиядән кайту белән районда иң зурлардан саналган «Михайловка» совхозында комсомол оеш-

масы секретаре, бераз соңрак Иске Карамалы мәдәният йорты директоры вазифаларын башкара. Әмма югары белем алу теләге барыннан да көчлерәк булып чыга һәм Казан дәүләт университетының тарих-филология факультетына укырга керә. Керә... дип әйтүе генә җиңел! Укырга китәргә җыенганын белгәч, ул чордагы җитәкчеләр аңа бернинди дә документлар бирмиләр. Кулда — хәрби билет, култык астында — бер кочак шигырьләр. Аның университетка кабул иткәндәге бөтен документлары шуннан гыйбарәт була. Укуны тәмамлагач, диплом яклаганда ук аспирантурада калырга үгетлиләр. Диплом эше студентларның фәнни конкурсында җиңүчеләр исемлегендә була. Ләкин егет гаилә хәлләре буенча авылда төпләнеп калырга уйлый.

Шулай итеп, ул Мөслим районы Октябрь авылында укытучы булып эшли башлый. Гаилә корып җибәргәч, туган авылына кайтып, әдәбият, тарих фәннәре укыта. Ләкин 1981 елда, Октябрь мәктәбендә эшләүче укытучыларның соравы буенча, директор итеп билгеләнә. Тагын берничә елдан районда иң эре саналган Тат.Бүләр урта мәктәбенә директор итеп җибәрелә. Ләкин язмыш Факил Сафинны 1984 елда Чаллы шәһәренә алып килә. Ул КамАЗның автомобильләр җыю заводында баш конвейерда слесарь-җыючы, бригадир, мастер булып эшли. Эш дәверендә 1 классны мастер дәрәҗәсенә ирешә, КамАЗның Мактау тактасына кертелә, Минавтопром буенча җиңүче була. Язмыш Ф.Сафинны гел бөтереп кенә йөртә: ул яңадан мөгаллимлек эшенә кайта, 24 нче һәм 18 нче мәктәпләрдә тарих укыта. Шәһәр тарихында беренче мәртәбә 8 классларга кадәр «Татар халкының тарихы, әдәбияты, мәдәнияте» дигән яңа фән-дәресләр укыта башлый.

Шушы елларда аның исеме шәһәр матбугатында күренә башлый. 1990 елда Факил Сафин, Әмәк тәхәллүсе алган язучы, шагыйрь шәһәрдә үз чорында данлыклы исем алган «Таң йолдызы» газетасына баш мөхәррир урынбасары булып эшкә килә, 1991 елда исә «Аргамак» журналының җаваплы сәркатибе итеп сайлана.

Исеме танылып кына килгән яшь язучыга өлкәнрәк буын әдипләр зур ышаныч баглыйлар. Танылган язучы Газиз Кашапов: «Күңелеңдә булганны яз, каршылыклар күп булачак әле ул»,— дип фатиха бирсә (Нинди күрәзәчелек! Факил Әмәкнең тормыш юлы күп очракта башкалар китереп өйгән каршылыкларны җиңә барудан гына тора), күренекле шагыйрь Кадыйр Сибгатуллин: «Син — шагыйрь. Үзеңне хөрмәт итәм, иҗатыңны яратам. Берүк чор ыгы-зыгысына ияреп ваклана күрмә»,— дип (Факил ваклыклардан өстен тора бelә!), аркасыннан сөя.

Бүген Факил Сафин — күренекле әдип, шагыйрь, мәртә-

бәле сүз остасы. Алай гына да түгел, иҗтимагый актив һәм үз кыйбласына турылыклы кеше буларак, ул Чаллы шәһәрендә чыга торган «Мәйдан» журналының оештыручысы һәм баш мөхәррире дә. Чаллы югары уку йортларында студентларга дистәләгән лекцияләр укыган мөгаллим, беренче шәһәркүләм балалар иҗат түгәрәкләрен оештыручы, «Ләйсән» әдәби иҗат берләшмәсенең җитәкчесе булуын, күпсанлы шигырьләргә көйләр язучы үзешчән композитор икәнлеген дә искә алсак, бу кешенең эрудициясенә, көченә, тырышлыгына хәйран каласың. Ул дистә ел эчендә бер-бер артлы «Соңгы көз» (1992) һәм «Гөлҗиһан» (1998) повестьларын, «Биек тауның башларында» (1998) романын һәм «Саташып аткан таң» (2002–2003) роман-трилогиясен иҗат итте, «Сәфәр» (2002) шигырьләр җыентыгын бастырып чыгарды. Шул рәвешле лаеклы рәвештә олпатлар мөнбәреннән урын алды.

Һәр чор үз әсәрен тудыра.

Хәтерлим, заманында Мөхәммәт Мәһдиевнең «Без — кырык беренче ел балалары» әсәре тын кырмыска оясын туздырып җибәргәндәй бер әсәр булган иде. Факил Сафинның «Соңгы көз» повесте да гавам күзгесендә әнә шундыйрак эз калдырган әсәр булды: чөнки ул тоталитар режимны — димәк, гомуми коллыкны рәхимсез рәвештә фаш итте. Әйе, «Тора-бара бөтен власть беренче секретарьлар, өлкә, шәһәр, район башлыклары, завод-фабрика, колхоз-совхоз җитәкчеләре кулына күчте. Алар аерым булып оештылар. Тирә-юньнәрен куштаннар, ялагай бәндәләр белән уратып алдылар. Кода-кодагыйлык, ришвәтчелек, мораль һәм җенси бозыклык, эчкечелек чәчәк атты. Үзләре генә шулай яшәсәләр бер хәл иде. Алар карьеристлар һәм әләкчеләр, һәр төрле җинаятьчеләр өчен уңай шартлар, җирлек тудырдылар. Туры сүзле, намуслы кешеләргә яшәү нык кыенлашты, аларның бер тиенлек кадере калмады. Гади хезмәт кешесенә тәмам көн бетте» (Ф.Миңнуллин. «Балта явызлар кулында»).

Факил Әмәкнең «Соңгы көз» әсәре бу нәүбәттән Аяз Гыйләҗевның «Балта кем кулында?» әсәре белән аваздаш булды. «Соңгы көз» повестеның төп герое Тимерхан Заманов — шул тоталитар системаның шактый зур кодрәтенә ия вәкиле. Үз төбәгендәге чикләнмәгән властьны аңа партия мәктәбендә бергә укыган сабакташы — КПСС өлкә комитетының беренче секретаре «бирә». Повестьтагы барлык каһарманнарның эчке һәм тышкы дөньялары, кыланмышлары һәм эш-гамәлләре Замановка бәйле рәвештә ачыклана; шуңа күрә дә аларны Замановка «буйсынучылар» яки «буйсынмаучылар» дип атарга мөмкин булыр иде. Тик ул үзе дә «ирекле» кош түгел: аның кул астында кешеләр ул кылган җәбер-золымнарга ничек итеп тешен кысып түзсә, үзеннән

югарыда утыручы түрәләр каршында ул үзе дә мескен хәлдә — ул аларны сыйлый, көйли, чөйли, яраклаша, ялагайлана. Чөнки системасы шундый. Мондый система яшәгәндә, беркем дә тулы вә тигез бәхетле була алмый; алар — түрәләр! — намусын, горурлыгын сату бәрабәренә ниндидер ләззәт рәхәтлекләр алса да, ахыр чиктә барыбер бәхетсез кешеләр. Чөнки алар да система коллары!

Тимерханның әтисен утызынчы елларда, социализмны астан җимерә дип, нахакка кулга алалар. Әнисе ашлык тапшырырга киткән җиреннән кайтмый. Яшьтәшләре, мәктәп укучылары Тимерханны «халык дошманы» малае дип кагалар, кимсетәләр. Сабый чагыннан ук «халык дошманы» малае буларак, Тимерхан рухи гариплек кичереп, горурлыгы кимсетелгән кеше булып үсә. Шуңа да яшьлегендә акыл, киңәш бирүче Бәйрәмгали бабайның: «Син, улым, кешеләргә беркайчан да ышанма. Дус-ишләрдән сак бул... Үзеңә ышан, нык бул, үҗәт бул! Хәзер әрсезләр заманы. Туры килсә, тимер арканны да тешләп өз. Юашны тиз юешлиләр. Гаделлекне эзләп тә җәфаланма — гаделлек юк ул дөньяда! Мәгәр минем әлегәчә күргәнем булмады. Кем көчле, шуның сүзе үтә, кемнең кулында — шуның авызында! Өермәдәй бөтерел, еландай боргалан! Башыңны койрыгыңнан, койрыгыңны башыңнан эзләсеннәр. Шул чагында яши алырсың»,— дигән өйрәтмәсе аның яшәеш рәвешенә, тормыш итү принцибына әверелә.

Бәйрәмгали бабай киңәшләрен исеннән чыгармаган «халык дошманы» малае колхоз рәисе дәрәҗәсенә күтәрелү өчен күп көч, зур тырышлык сарыф итә. Заманов, сүз дә юк, эшлекле кеше. Ул — гаярь, тырыш җитәкче. Хуҗалыкны алып бара белә. Шул ук вакытта ул үтә дә хәйләкәр. Эшне шундый итеп оештыра ки, авылдашлары аның алдында үзләрен йә һәрдаим гаепле сизеп йөриләр, йә булмаса, һич уйламаганда, колхоз рәисенә бурычлы булып калалар. Чөнки заманасы шундый.

Социализм, гомумән, күз буяучылыкка корылган икән, Заманов аның «идеаллары»н осталарча тормышка ашыручы. Әйтик, Заманов җитәкләгән колхозда нинди дә булса төзелеш эшләре башлана икән, бөтен тирә-юнь шау-гөр килергә тотына. Мәсәлән, авылның «яңару» күренешен генә күз алдына китерик. Таза нарат йортлар «өске» урамда гына төзелә, чөнки анда авыл түрәләре яши, «аскы» урамда йортлар черек усактан салына, юллары батып үлмәле, монда хәерчелек хөкем сөрә. «Өске» урам социализмы белән «аскы» урам социализмын Шәмсетдин агайның төпчек улы үзенчә бик төгәл аңлатып бирә: «Прастуй гына әйткәндә, «социализм» дигәне — Суарның аскы урамы; «нык үскән социа-

лизм» дигәне өске урам була инде. Бөтен җитәкчеләр шул үзәк урамда яши... Тик социализмның да юлында бер охшашлык бар: тегендә дә, монысында да гаделлек юк. Кемнең кулында, шуның юлында; кем көчле, шул җиңә».

Тимерхан Заманов ничек кенә гайрәтле булмасын, үзе дә командачыл бюрократик системаның, үзеннән югарыда утыручыларның колы. Үз чиратында, Заманов үзеннән түбәндәгеләр белән бик оста һәм шәфкатьсез идарә итә белә. Үзенең колхозында Заманов — бердәнбер хөкемдар. Ул үзе тирәсенә куштаннар туплаган. Әйтик, баш агроном Фәйзи, авыл советы рәисе Әнүр, парторг Инсаф «хөкемдар»га берсүзсез буйсыналар, аңа ярарга тырышалар. Кул астында эшләүче кечкенә түрәчекләр белән Заманов дорфа, тәкәббер. Чөнки шунсыз аны «ихтирам итмәячәкләр», ул айт дигәндә, тайт дип калтыранышып тормаячаклар. Кем әйтмешли, аның иртәнге планлаштыруны үткәрү күренешен, чорның сурәте буларак, «кинога» төшерерлек: «Белгечләр иң элек баш агроном Фәйзи Солтанов янына керәләр. Төгәл алты тулуга, кыр казлары кебек тезелешеп, рәис бүлмәсенә юнәләләр. Гадәти генә керү түгел бу, үзенә күрә бер церемония! Сафның башында — Фәйзи Солтанов, аның артыннан баш зоотехник Хәсән Әгъләмов, партия оешмасы секретаре Инсаф Җиһанов, авыл советы рәисе Әнүр Сәйфиев, баш инженер Ясәви Бариев, аннары башкалар. Рәис бүлмәсендә утырганда һәркайсының үз урыны. Керүчеләр түргә узып, рәиснең дымсу, салкынча кулын кысканнан соң, урыннарына барып утыралар. Аларга рәис күз дә салмый, кәгазьләр караштырган килеш илтифатсыз гына якынайган шәүләгә кулын суза».

Әйе, хакимият — аяусыз көч, усал, явыз, башбаштак көч. Тимерхан Заманов моны бик яхшы аңлап эш итә. Шуңа күрә дә ул корбаннар эзли, кеше намусын изеп үтү аңа берни дә тормый. Повестьта иң беренче корбан — Замановның никахлы хатыны Зөлхиҗә. Әсәрдә тетрәндергеч бер күренеш бар: «Ә Зөлхиҗәсе Тимерханның хатын-кыз затына һәвәслеген күрмәмешкә салыша иде. Һай, күп булдылар алар яшәгән гомерендә. Хатыны, вафаты алдыннан, үз-үзенә сөйләнгәндәй итеп: «Эчемдә гомер буе утлар янды. Кешеләргә сиздермәс өчен йөрәк каным белән сүндердем. Шул алып китә гүргә»,— дип, күз яшьләрен сөртеп алган иде. Тимерхан эндәшмәде. Иңенә җылы бишмәтен салып, ишегалдына чыгып китте».

Кансызлыгы, имансызлыгы, кабахәтлеге, хәйләкәрлеге ягыннан Заманов Ф.М.Достоевскийның «Җинаять һәм җәза» романындагы Свидригайлов образыннан ким түгел. Эткә эт үлеме дигәндәй, аларның үлемендә дә охшаш мотивлар юк түгел. Ә аның «свидригайловлыгы» тагын бер күренеш-

тә ачык чагыла. Ул хатыны каберенә килеп «баш ору» гадәтеннән дә зур тамаша ясый. Һәр елның 15 октябрендә мәктәп укучылары көзге уңыш җыярга басуга чыккан көнне Заманов дистәләгән күз озатуында зират капкасы каршына килеп туктый. Кабер янында Тимерханның кылган эш-гамәлен, эшләреннән бүленеп, йөзләрчә укучылар һәм укытучылар карап-күзәтеп торалар. Ул күздән югалганчы озатып калалар. Әйе, Замановның һәр кылган эше макталырга, хупланырга тиешле, хәтта аның хатыны Зөлхиҗә каберенә зыярат кылуын да кешеләр күреп, бәһаләп торырга тиеш. Тик шунысы гаҗәп, бу минутларда Тимерханның миеннән «Зөлхиҗә!» дигән уй ялгыш та үтмәде».

Икенче бер корбан — Гөлчирә. Өч яшьлек кызның — Гакыйләнең әнисе, абзар артында, баганага сөялеп үкси: «Исрафилкаем, теләсә ни эшләт. Тимерхан... кара йөз... мыскыл итте... кабахәт!..

Тимерханның исемен ишетүгә... ир хатыны янына чүгәләде:

— Нигә шыр акырасың?.. Персидәтельнең исемен әйтмәй генә аңлатып бир, дөньяны сасытасың бит...»

Тәнкыйтьче М.Вәли хаклы язып үткәнчә: «Халыкны мондый хәленнән чыгару өчен күпме кирәк?! Хәтта үзенең хатынын көчләүгә белән ризалашкан һәм каршы бер сүз дә әйтә алмаган кешеләрне, чыннан да, кеше итү өчен әле никадәр көч салырга кирәк булачак милли әдәбиятка».

Корбаннар, корбаннар... юллар, юллар...

Чираттагы корбан — Гөлчирә белән Исрафилның кызлары Рәхилә... «Кыз үксүеннән туктады, әрнеп:

— Безнең гаиләнең бәхетен урлаган кеше син. Инде минем дә башыма җиттең... Ни йөзем белән өйгә кайтыйм, кеше күзенә күреним?» — диде.

Моны «свидригайловщина» димичә ни дип атарга мөмкин соң?!

Ф.Сафинның «Гөлҗиһан» повесте — актуаль проблемаларны чагылдырган, тормышчан образларга бай әсәр. Беркемгә дә сер түгел: шагыйрьләр үз иҗатларында шигырь гармониясен, шигырь үлчәмнәрен аеруча сизгер тоючан. Әгәр дә шагыйрь чәчмә әсәр язуга алына икән, ул, ирексездән, үзе дә сизмәстән, проза әсәрендә шигырьгә хас югары поэтика кануннарын куллана башлый һәм әсәрдәге образлылык чын мәгънәсендә камиллеккә ирешә. Чәчмә әсәр укыганда «җырлап тора» башлый, күңелгә рәхәтлек бирә, укучыда фикер өермәсе кузгата. Теленең табигый агышы, гыйбарә-төсмерләргә бай булуы, сыгылмалы рәвеше белән «Гөлҗиһан» повесте хәзерге татар прозасының бер казанышы булып тора. Моны зәвыклы һәм таләпчән укучы да тиз сиземләп алды.

Әсәр китап булып басылып чыккач ук, 1999 елда республика күләмендә иң күп укылучы китап исеменә лаек булып, I дәрәҗәле Диплом белән бүләкләнде һәм язучы Чаллы шәһәрендә Ел язучысы исемен алды.

Әсәрнең үзәгендә — сугыштан соңгы авыр тормыш кичергән, әмма рухи сынмаган, хис-кичерешләргә бай татар хатыны язмышы. Әсәрнең сюжеты да төп герой — Гөлҗиһан тирәсендә үрелеп бара. Гөлҗиһанның тормышын тасвирлаганда, автор кеше күңеленең матурлыгын, изге җанлы булуын катлаулы вакыйгалар, уйлап чыгарылган каршылыклар аша түгел, ә бәлки гади, тормышчан хәл-әхвәлләр эчендә ача. Гөлҗиһанның уңганлыгын, матурлыгын, гадилеген, шаянлыгын тасвирлау белән бергә, Ф.Сафин аны уратып алган, тормышыбызда яшәп килгән аерым тискәре күренешләрне дә онытмый. Шул ук вакытта әдәп, әхлак, гаилә проблемаларын да күтәрә. Гөлҗиһан чын күңелдән кешеләрне, тормышны ярата; ул — ярдәмчел, кешеләргә игътибарлы!

Гөлҗиһан — колхоз рәисе кызы. Ул бик яшьли ятим кала. Әтисе исән булса да, кыз ата назын күрми: «Сугыштан кайтканнан бирле әтисенең балалары белән иркенләп, җайлап сөйләшкәне булмады. Әниләренең үлеменә дә балаларын гаепле санаган кебек». Ләкин авырлыкларга карамастан, яшь, гүзәл Гөлҗиһан киләчәккә өмет, ышаныч белән карый. Тормышында авырлыклар очраганда, Гөлҗиһан саилче карчыктан отып алган җырны көйләргә ярата:

Бер кайгыга батам, бер юанам —
Миндәйләр күп дөнья йөзендә.

Ахырда яшьлек, мәхәббәтне сагыну хисе йөрәктә бераз томалана барганда, яратмыйча кияүгә чыккан ире Әүхәткә күңеле ияләшә төшкәндә, йөрәктә яшәү дәрте — берәр малай үстерү теләге тернәкләнеп килгәндә, язмыш Гөлҗиһанны тагын бер авыр сынау алдына куя. Табигатьне, чисталыкны яраткан, намуслылыкны үзенә юлдаш иткән мәрхәмәтле җан иясе кичереп булмаслык шәфкатьсезлек — хыянәт белән очраша. Әле кайчан гына: «Һәр кеше үз тиңен эзли... Фәймә миңа тиң түгел», — дип йөргән Әүхәт язмышын башкача хәл итә: «Без ни... Фәймә белән ниттек... Горькийда ирле-хатынлы яшәдек. Аңа өйләндем. Авырлы инде ул... Без инде, Гөлҗиһан, кискән ипи ябышмас, әйбәтләп кенә аерылышыйк».

Шушындый авыр минутларда да Гөлҗиһан сабыр булып кала белә, кычкырып елап җибәреп, күрше-күлән алдында да, Фәймә белән Әүхәт алдында да үзен сынатасы килми, көчле рухлы булып кала. Бары эчтән генә: «И дөнья, нигә мәрхәмәтсез син бәндәләреңә?» — дип кенә сыкрана.

Әйе, Гөлҗиһан — шәһәр цивилизациясе алып килгән рухи шапшаклыклар белән пычранмаган ихлас-саф, беркатлы-күндәм, эшчән-тырыш саф татар авылы хатыны. Дөньяга дәгъва кылып, кычкырып-акырып йөрми, үз эшен тиешенчә башкарып килә; шуның белән ул Сәкинә, Фәймә, Гөлзадәләрдән өстен тора һәм шушы сыйфатлары белән укучы күңелендә ихтирам уята.

Факил Сафин каһарманнарның кешелек сыйфатларын тулырак ачу өчен мифик геройлардан оста файдалана. Әйтик, Гөлҗиһанның тормышында иң авыр вакытларда аның янында каяндыр, әйтерсең лә күктән иңгән кебек, бик тә ягымлы һаман да шул саилче карчык пәйда була. Әнисе үлеменнән соң да, газиз баласы яшәү белән үлем арасында ятканда да, Әфүзә күп еллардан соң кайтып төшеп, ташлап киткән малае Шамилне даулап йөргәндә дә, аның янына шушы саилче карчык килеп чыга: «Ходайдан аерылмагыз, балалар,— диде.— Аллаһ рәхмәтеннән ташламасын бәндәләрен. Исән кеше өметтән аерылмасын. Кешене өмет яшәтә».

Берни белән дә башкалардан аерылып тормаган бу татар хатыны, нәкъ менә Татар хатыны, тормыш итәргә гаҗәп тә үҗәт, нинди генә югалтуларга да карамастан, ул яшәргә тырыша, үзеннән соң да тамырларын калдырырга тели. Бу нәүбәттән, бу сыйфатларның Хәсән Сарьянның «Бер ананың биш улы» әсәрендә Ана образына салынган фикерләр белән уртаклыкны әйтү урынлы булыр. Өч улын югалткан Маһисәрвәр дә, Гөлҗиһан кебек үк, кайгыларга сабыр гына түзә. Бу образларның икесенә дә яшәү көче, диннән килгән Коръәни сабырлык хас. Аларны саклап килгән көч тә шул дини тәрбиядер әле, мөгаен. Кыскасы, Гөлҗиһан — чын мәгънәсендә татар хатыны образы, шуның белән ул татар әдәбиятындагы Аналар образы галереясын тутырып тора.

Факил Сафинның татар җанын тетрәткән тагын бер әсәре, ул да булса «Биек тауның башларында» романы. Алдан ук әйтеп куярга кирәк: бу әсәр киң җәмәгатьчелекнең игътибар үзәгендә булды һәм язучыга бу әсәре өчен лаеклы рәвештә Татарстан Язучылар берлегенең Гаяз Исхакый исемендәге бүләге бирелде. Әсәрдә сүз туксанынчы елларда күпләребезнең бәгырьләрен телгәләгән фаҗига — мәгънәсез Чечен сугышы, әле үсмерлекләреннән дә чыгып җитмәгән егетләребезнең һәлак булулары, армия хәлләре, экстремаль хәлләрдә адәм балаларының бер-берсенә булган мөнәсәбәтләре, беренче мәхәббәттән өзгәләнүләре тасвирлана. Әйе, бу роман егерменче гасыр ахырында татар дөньясы, аның аерым шәхесләре, милләт кичергән кайгылы вакыйгалар турында. Бу хакта әдип бер әңгәмәсендә: «Бу турыдан-туры халык

өстенә ишелеп төшкән фаҗига генә түгел, ә Рәсәйдәге милләтара сәясәтнең ни дәрәҗәдә гарипләндерелгән булуы хакында. Һәм шул сәясәт аерым бер милләткә генә, бу очракта Рәсәйнең чечен халкына каршы алып барган сугышның кайтавазы гына түгел, ул башка милләтләргә дә йогынты ясый... Минем исә шушы сәясәтнең гап-гади татар гаиләсенә тәэсирен күрсәтәсем килде», — дигән иде.

Яшәү рәвешебез кушканча, башта пионерда, аннары комсомолда тәрбияләнеп, Совет иленә, аның армиясенә дан җырлап, гадел хезмәт белән көн күрүче авыл кешеләре гаиләсендә туып-үскән, үз гомерендә әле туган авылыннан башка җирне күрмәгән үсмер-солдат Шәфкать, гаскәри хезмәткә алынгач, кырыс чынбарлык белән йөзгә-йөз очраша. Юк, туган авылын, әнисен, әле унсигез яше дә тулмастан, кичтән генә (мулла никахы белән генә) өйләнеп киткән хатынын сагынып елап утырмый ул. Күңеленең үксүе бүтәннән, тормышның миһербансызлыгыннан чарасыз егет. Аның туган авылында кешеләр мондый түгел бит! Алар туры сүзлеләр, каты куллылар, гаделләр — тик миһербансыз түгелләр. Факил Сафин әдәби әсәрләренең тууы хакында болай дип яза: «Әдәби әсәр образлары төрлечә туа. Кайберәүләре гел прототиплардан гына туганнары була. Автор тудырган уйдырма геройлар гына да булырга мөмкин. Әлеге романны мин 1994 елның декабрендә үк, Чечен иленә Рәсәй гаскәрләре бәреп кергәч тә яза башладым. Мөселманга каршы корал күтәрүгә мәҗбүр ителгән татар егете кичерергә тиешле хисләр бик тетрәндерде. Чөнки «Бүлгәлә һәм хакимлек ит!» сәясәтен башка милләт куллары белән гамәлгә ашыралар. Шуңа күрә, табигый ки, минем геройларым да автор хыялында туган уйдырма геройлар».

Ләкин шунысы ачык, геройлар уйдырма булсалар да, әсәрдә бернинди дә ясалмалык юк. Әсәрдән аңлашылганча, самими авыл егете Шәфкать тормыш авырлыкларын, яшәү өчен көрәшне ничек алып барырга кирәклеген, армиянең нинди җитди фаҗигаләргә китерергә мөмкин икәнен әле аңлап та җиткерми.

Бөек рус әдәбиятының XIX гасыр әсәрләреннән күренгәнчә, Россиядә солдатка гомер-гомергә кадер-хөрмәт булмавы мәгълүм. Һәм Ф.Сафинның бу әсәрен укыгач, моның шулай икәнлегенә тагын бер тапкыр ышанасың: «Яшь солдатларның күзләре керфек тә кагып алмаслык дәрәҗәдә киереп ачылган, алардан көлтә-көлтә шикләнү-шөбһәләнү, хыялланыр дәрәҗәдә курку чәчелеп тора... Алар кая куйсаң, шул якка ташланырга әзер хайван көтүе хәленә килеп җиткәннәр иде... Шәфкать тагын шунысын сизеп алды, ишек төбендә бар көчләренә көрәшкән бу шашынган күзле егет-

ләрнең һәркайсы әчләреннән ярсый-ярсый елыйлар, шушы тар ишек төбенә шәрә килеш китереп бастырган язмышларын, бар дөньяны ләгънәтлиләр иде кебек».

Шушындый гайре табигый шартларда армиядән исән-сау әйләнеп кайту күп көч, сабырлык таләп итә, чөнки армиянең үзенең катгый һәм аяусыз законнары бар. Иң мөһиме — бер уставта да каралмаган «ясалма» кануннарны яхшы белү һәм аны берсүзсез төгәл үтәү. Шушы кануннарга буйсынмаган өчен Шәфкатьнең җанын нык телгәлиләр, аңа аеруча взвод командиры ярдәмчесе өлкән сержант Головастиков каныга. Шәфкать мондый җәберләүләргә түзәргә тырыша. Армиядә дә шәфкатьле кешеләр бөтенләй үк юк түгел икән. Кече сержант Веремеевның: «Түз, түз, сине өйдә көтәләр. Шулар хакына кагу-сугуларны да үткәреп җибәрә бел»,— дип үгетләве аңа көч вә дәрман бирә.

Факил Сафин әсәрдә сагыну-җирсү хисен зур художникларча бирүгә ирешкән. Бу хис Шәфкать образын төгәлрәк ачарга, аның кичерешләрен тагын да тәэсирлерәк тасвирларга ярдәм иткән: «Шәфкать нигәдер үз авылын, Имәнле Тау ягыннан искән нәзек җилне искә төшерде һәм тамак төбенә ачы төер килеп утырганын сизде. Юк, ул җилне юри генә «зәһәр» диләр бугай. Шулкадәр йомшак, рәхәт булып исә бугай ла ул Имәнле Тау җиле. Туган як җиле бит ул, ягымлы, битләрне иркәләп исә торган туган як җиле».

Шушы сагыну хисе Шәфкатькә яшәү көче бирә!

Факил Сафин кайчагында шундый тәэсирле «куе» буяулар куллана ки, тәннәр чымырдап куя. Әйтик, табутта аның урынына частька килгәннең беренче көннәреннән үк Шәфкатькә рәхим-шәфкать күрсәтмәгән капитан Хасистовның (фамилиясенә игътибар итик!) күмергә әйләнгән гәүдәсе кайтып төшү күренеше үзе генә дә ни тора...

Факил Сафин — татар әдәбиятының борынгы традицияләренә тугрылыклы язучы. Ул Шәфкатьнең сөекле хатыны Раушанияне шундый югарылыкка күтәрә ки, ирексездән борынгы бабаларыбызның яудан кайтуын көткән тугрылыклы хатыннарның изге образлары күз алдына килеп баса. Әйтик, иренең Чечен илендә әсирлектә икәнен телевизордан күреп белү белән үк, һич икеләнмичә, Раушания юлга чыга. Бирედә символик мәгънәгә ия бер яшерен агым бар — Сөләйман исемле чечен егете әти-әнисен, туганнарын дошман һөҗүменнән якларга, Раушания исә «дошман булып басып кергән», әмма әсирлеккә төшкән ирен кайтарырга ашыга.

Мең газаплар белән сугыш барган җиргә килеп җитеп, ирен таба алмый тилмереп йөргәндә, пулялар яңгыры астында чиләк тотып яралыларга суга дип барган җиреннән ул Шәфкать танкының корбаны булырга тиеш була, чөнки ка-

питан Хасистовның боерыгы шундый: юлда очраган бер генә җан иясен дә аямаска!

Ә тормыш язмышларны үзенчә хәл итә! Күңел, җан һәм тән берлеге үзен сиздергән, күрәсең, Шәфкать, каршындагы шәүләнең Раушания икәнлеген шәйләп алганнан соң, танкын ташлап аңа ташлана, ә капитан Хасистов кулына күчкән танк, Шәфкать белән Раушанияне юкка чыгарырга өлгергәнче, минага эләгә...

Әйе, үлем яхшы кешеләрне генә сагалап йөри, дисәк тә, кайчакта ул яхшы кешеләрне дә читләтеп үтә икән. Чөнки алар — Шәфкать белән Раушания Яшәүгә мәхкүм ителгәннәр, алар бит бу якты дөньяга бәхетле булырга килгәннәр һәм алар шуның өчен бергә кушылдылар да! Изге җаннар озак яшәргә тиеш!

Кыскасы, тарих кабатлана тора. Әле кайчан гына булып узган әфган сугышын меңнәр вә миллионнар «бу сугыш ялгыш булган икән» дип бәяләделәр... Ә Чечен сугышы?! Ул да кешелекнең чираттагы ялгышы түгелмени?! Ялгышы, әлбәттә. «Биек тауның башларында» әсәрендә Факил Сафин моны нәкъ шулай итеп ачып бирә дә инде.

Әйе, Факил Сафин бүгенге татар әдәбиятының күренекле прозаигы булып танылды. Аның иҗаты күзгә күренмәс җепләр белән Г.Ибраһимов, Г.Исхакый, Ә.Еники, А.Гыйләҗев, М.Мәһдиев, Х.Сарьян, Ф.Садриев иҗатлары традициясенә килеп тоташа.

Бу нәүбәттән Факил Сафинның иҗаты күп кенә күзәтүләргә этәрә. Иң начар роман шул, әгәр укучы аның ни белән бетәсен белгертә алмаса (ә Факил Сафин әсәрләренең азагын көтеп аласың). Бу сүз уйнатуда чынлап та дөреслек юк түгел. Романның иң зур уңышы шунда ки, ул укучының күңелендә кызыксыну белән бергә, кичерешләр, ярдәм итәргә ашыгу хисләрен дә уятырга тиеш.

Сүз дә юк, әдәбият реаль тормышка әйләнгеч юллардан алып килү чарасына әйләнергә тиеш түгел. Шушы мәгънәдә без әдәби әсәр белән чынбарлык арасындагы үзара бәйләнешләрне өйрәтергә тиешбез. Теләсә нинди роман, баштарак ул ничек кенә кызык тоелмасын, чынбарлыкны чагылдырмый икән, ялган һәм кызганыч язмышлы. Шуңа күрә дә без әдәби әсәргә, бу очракта роман белән повестька, тормыш һәм яшәеш күзлегеннән чыгып бәя бирергә мәҗбүрбез.

Бер француз әдәбиятчысының билгеләп үтүенчә, кешелек һәрвакыт яңа аллалар эзли. Һәртөрле йола, гореф-гадәтләрне, яшәеш кагыйдәләрен онытмаган хәлдә. Тормышта бары тик эволюция генә реаль. Шуңа күрә дә шушындый

бәрәкәтле яшәеш тәҗрибәсеннән баш тарту — үзе үк ахмаклык һәм, һичьюгы, беркатлылык булыр иде. Романчы буларак (Факил Сафин нәкъ менә романчы буларак фикер йөртә), аның «күңел күзен» реаль чынбарлык кына түгел, ә бәлки тирәнтен яшерелгән, беренче карашка күзгә бәрелеп тормаган уйдырма чынбарлык та җәлеп итә. Дөресрәге, ул реаль чынбарлык җирлегендә икенче бер чынбарлык иҗат итә. Болай дигәндә, ирексездән Ф.А.Достоевскийның А.С.Пушкинга һәйкәл ачылганда ясаган чыгышында әйткән сүзләре хәтергә килә: «Дөньялыкны матурлык коткарыр!» Ә талантлы әсәр һәрвакыт тудырылган матурлык ул!

* * *

...Шулай бервакыт якташыбыз шагыйрь Зөлфәтнең эш бүлмәсендә сөйләшеп утырганда, Факил Сафин ниндидер тантана белән: «Мин озак вакытлар Мөслим ягы шигърияте ндәге «Бермуд өчпочмагы»ның кайчан да булса өченче почмагы да пәйда булырга тиеш дип уйлап йөрдем. Ике почмагы ул — Зөлфәт белән Харрас Әюп! Менә, ниһаять, өченче почмагы да булды, монысы син, Наис абый!» — дигән иде.

Шушы фикерне дәвам итә калсак, инде болайрак дип әйтергә мөмкин булыр иде: Мөслимдә прозаикларның да үзенчәлекле «өчлеге» хасил булды. Алар — Фоат Садриев, Флүс Латыйфи һәм Факил Сафин. Димәк, Мөслим төбәгенең иҗади сурәте хәзергә тәмам өлгереп җитте. Әмма әдәбият мәйданында һәркемгә дә урын җитәрлек. Кем әйтмешли, үз дөньяларын тудыра алырлык талантлар гына туа торсын...

...Факил Әмәк турындагы язмамны мин Хәсән ага Туфанны искә алып башлап киткән идем, сүземне дә олуг шагыйрьнең (әйтерсең лә шушы очракка атап язылган!) бер шигыреннән өзек белән тәмамламакчы булам:

Талантлы син, Кеше туганым! —
Сәләтлесең һәрбер иҗатка;
Дөнья дигән Бөек китапка
Языла бара хезмәт юлларың.
Талантлы син, Кеше туганым!

P.S. Ә ошбу китапка урнаштырылган «Саташып аткан таң» роман-трилогиясе тирән фәлсәфә, җанны кузгатырлык кичерешләр, әдәбиятта моңарчы күтәрелмәгән фикер һәм тема катламнары, фактик материалларның муллыгы белән аерылып тора. Шәхес һәм Дәвер, Әхлаклылык һәм Гаделсезлек, Намус һәм Хыянәт, Хыял һәм Чынбарлык, Мизгел һәм Мәңгелек, Мәхәббәт һәм Нәфрәт, Тугрылык һәм Яраклашу. Әсәрдә күтәрелгән бу проблемаларга укучы үзе бәя бирер һәм нәтиҗә чыгарыр дип ышанасы килә.

*Наис Гамбәр*

«...Бәлки, аны искергән тема дип уйлаучылар булыр. Халык язмышында фаҗига искерми. Үткәннәрне искә төшереп без киләчәкне кисәтеп куябыз...»

*Туфан Миңнуллин*

# ПРОЛОГ

*Беренче очрашуым Сакмар белән. Ашкынып, ярсып ага икән. Дулкыннар үзара туктаусыз сөйләшә, бәхәсләшә, вакыт-вакыт чытлыкайланып көлешеп тә алган булалар. Бу якты дөньяда бер эше юк аларның; бәхет диме, ни дисең?..*

*Җәй эссе килгәнлектән, шактый саеккан күренә елга. Биек яр итәге белән кояш нурлары качышлы уйнагандай елык-елык балкып аккан елганы комлы үзәнлек аерып тора.*

*Беренче карашка гына шулай гамьсез, битараф тоеладыр Сакмар. Яңгырлар гына башлансын, үзәнлекне су ташкыны йотар, Сакмарыбыз чын холкын күрсәтәчәк — күрсәтәчәк инде — ярдан ярга бәрелә-сугыла Җаек ягына ашкыначак ул, юлында ни очраса, берсен дә аям тормаячак, шашкын кочагына эләксәң, үзенә ияртеп, дөньяның әллә кай тарафларына илтеп ташлаячак. Күңел шулай тоя.*

*Сакмар буена таралып утырган Каргалыга килеп җитеп, хуҗалар белән танышып алуга, ниндидер тыелгысыз дәрт, ымсыну белән бормалы сукмактан елгага төшеп киттем.*

*Хуҗаның юлдашларымнан сораганы колакка эленеп калды:*

*— Бу егет кем була соң? Ул да безнең агай-энеме дисәм?..*

*— Язучы, Чаллыдан.*

*— Кит инде, язучы шулай буламыни? Парашюттан тундрага ташлап киткән чүл гарәбе кебек аптырап йөри...*

*Чал чәчле юлдашым мине яклап нидер әйтте бугай, көлешеп алдылар.*

*...Сакмар буе сары тал... Бусы халык җыруы. Көен белмим менә. Таллар күзгә шәйләнә шәйләнүен.*

*Су буена килеп басуга, әллә тагын мине көтеп торганнар, бер-бер артлы өч-дүрт дулкын, чал ялларын уйнатып, аяк астына ташландылар да тубыктан суга чумдырып алдылар, ниндидер шәп гамәл кылган бала-чага*

*кебек сөенә-сөенә тыйгысыз Сакмар эченә кереп югалдылар. Хәтта дулкыннарның чыркылдап көлгән тавышларына кадәр ишеттем бугай. Чак кына кыймылдауга аяк йөзеннән су чаптырып чыга, туфлиләремне салып, агарып торган зур таш өстенә куйдым да, тирән сулыш алып, тирә-якка күз салдым. Матур, бик матур Сакмар буйлары. Бераз түбәнрәк ике малай елга уртасына ук алып кергәннәр дә җирән тайларын шәпләп юындырып мәш киләләр. Ат малайларның әле берсенә, әле икенчесенә борынын төртеп алган була, пошкыра, су эчендә биеп тә алгандай итә, рәхәт чиккәне әллә каян күренеп тора. Яр өстендә кулын артка куеп, кыска ыштан кигән бер ирегет арлы-бирле йөренә. Таза бәдәне кояшта янып карачутыр төсенә кереп беткән, малайларына карап куанып туя алмый, ком өстендә вәкарь атлаулары шуңа ишарә.*

*Миннән югарырак, таллык буенда ике кыз, кармак сапларын килешле генә тотып, балык каптырырга маташалар. Хәзер заманасы үзгәрде, кызлар кармак сала, шәп балыкны алар каптырмакта. Шулай уйлап бетермәдем, таллык арасыннан, ике үсмер килеп чыктылар, кызлар белән әрепләшә башладылар. Китте чыр-чу, берберсен суга этеп төшерү дә калмады, мин авыз ачып торган арада ике кармак сабы дулкыннарның үзләрен уздырып еракта каралып күренгән таш күпер ягына агалар иде инде. Эх, малайлар, ни үзегез балык тотмыйсыз, ни балык тотарга азапланган кызларга көн күрсәтмисез. Дөньясы әллә нинди шунда.*

*Төшкән сукмакка борылдым. Ул калын алабута урманы эченнән үтә, ә ярның шәрә өлешеннән зур янгын эзе — көл-күмер катламы күренеп тора. Инде аны ике-өч метр ком баскан, шулай да кайчандыр бу тирәдә зур янгын булуына ишарә иде бу. Ярдан күтәрелгәч тә, тар гына урам, Каргалының йорт-ихаталары башлана бит.*

*Ярдан күтәрелә торган җирдән кисәк туктап, кире Сакмарга күз ташладым, карашым каршы яктагы шактый калын күренгән урманны айкап үтте. Ничектер аптыраулы халәттә калдым шушы мәлдә.*

*Ни дип килдем соң монда? Нәрсә эзләп йөрим, кем көтеп тора мине биредә? Беркем дә көтми, монысы ап-ачык. Ә менә нәрсәдер эзләп йөрүем хак. Әгәр берничә ел элек, син Каргалы-Оренбур якларын аркылыга-буйга йөреп чыгачаксың, дисәләр, шаркылдап көлгән булыр идем, чөнки бу якларда беркемем дә юк шикелле, ни калган миңа Сакмар-Җаек буенда? Хатыным күрше авылдан, Мөслим, Ык буе кызы, яшәгән җирем Чулман буендагы Чаллы каласы. Шулай булгач соң...*

*Бу сәфәрнең тарихы моннан ун ел элек — туксан*

*икенче елның җәенә барып тоташа. Ул елны җәй салкынча килде кебек, тыныч кына бүлмәмдә эшләп утырганда, ишек шакыдылар, мин ни дә булса эндәшеп өлгергәнче, ишектән чал чәчле бер абзый килеп керде. Күптәнге танышы кебек кул биреп күреште, хәл-әхвәл сорашты, каршымдагы урындыкка утыргач, ниндидер илаһи сере бар сыман күзләрен-йөзен балкытып, сүзсез генә миңа карап тора бу. Сизәм, кемдер, махсус дип әйтимме, нәкъ менә миңа мөрәҗәгать итәргә кушкан, ахры.*

*Сүзсез озак утырып булмый, эшнең тыгыз чагы.*

*— Ни йомыш, абзый кеше? — дим.*

*Агайның йөзе кинәт үзгәрде, җитдиләнде, хәтта кырысланды да шикелле. Кулындагы папкасын ачып кәгазьләр актарырга тотынды.*

*— Сезнең янга килдем, Марат Дәүләтъяров булам, — дип сынап миңа карап куйды.*

*Татарчасы авыр, әмма нәкъ менә үзебезнең телдә сөйләшергә тырышуы сизелә. Икеләнгәндәй сорады:*

*— Сез Дәүләтъяров дигән кеше турында ишеткәнегез бармы? — Абзыйның зәңгәр күзләреннән моңсулык сирпелде.— Яшьләр белми инде, сорашып караган бар...*

*Дәүләтъяров... Дәүләтъяров... Баш миендә нәрсәдер шәйләнә кебек. Әһә искә төште. Телгә килдем:*

*— Бераз гына... Беләсезме, Казанда, университетта укыганда бер әбидә фатирда тордым. Аның абыйсы Яһудин фамилияле булган. ТатЦИК рәисе булып эшләгән утызынчы еллар башында. Шул чорда авырып үлгән булса кирәк. Әби яшь чагында Ушков дигән купецта горничная булып торган, укымышлы, фәһемле кеше иде. Әбинең иң якын дуслары атаклы физик Мәхмүт Зариповлар гаиләсе иде. Берчакны әби янына профессор Зарипов килде хәл-әхвәлләрен белергә. Шунда аның авызыннан ишеттем Дәүләтъяров фамилиясен. «Шәп кадрлар бар иде, яшьләр, укымышлы татар егетләре. Харап булып беттеләр. Дәүләтъяров дигән егет үсеп килә иде. Ул да юкка чыкты»,— диде ул ачынып.*

*Шуларны сөйләгәч, сорау бирдем:*

*— Кем соң ул Дәүләтъяров, сезгә кем тиешле?*

*Абзыйның йөзе тартылды. Әкрен генә әйтте:*

*— Әтием ул минем...— Һәм ул әтисе Әхмәтсафа ага, әнисе Рабига Сарымсакова, борынгы Дәүләтъяровлар нәселе, күргән-кичергәннәре хакында түкми-чәчми бәян итте. Кичкә кадәр сөйләшеп утырдык. Ахырда гына Марат ага гозерен әйтеп салды:*

*— Үзебезнең шәҗәрәне төзегән идем, шуны журналда бастырып булмасмы дип йөрү. Бер истәлек булыр иде әти белән әнигә. Аларның каберләре дә юк бит...*

*Авыр хисләр эчендә утыра идем, искәрмәстән:*

*— Сез сөйләгәннәр хакында роман язарга кирәк тә бит. Безнең буын, бездән соңгы буынга сабак булсынга...*

*Марат ага чыгарга кузгалган җирдән кисәк миңа борылды һәм катгыйлык белән:*

*— Романны сез язачаксыз! — диде.*

*— Ничек? — аптырап калдым.— Ичмаса, үз гомеремдә Оренбур, Каргалы якларына барып чыккан кеше булсам ярар иде. Аннан соң бит, язучы буларак та танылган кеше түгелмен.*

*— Сез, һичшиксез, зур язучы булачаксыз.— Агай Пушкин, Достоевский, тагын әллә нинди бөек язучылар тормышыннан мисаллар, әсәрләреннән өзекләр китерергә тотынды.*

*Көлемсерәп тыңлап тордым. Һәр чагыштыру аксый диләр, монда бөтенләй аяксызлану китте.*

*— Соң Сез үзегез дә әдәбиятны бик яхшы беләсез ич. Язызыз берәр әсәр. Без укып, киңәшләр бирербез.*

*Абзый яктыра төште.*

*— Язып караган бар анысы. Әмма һәркемнең үз эше. Мин төзүче, зур төзелеш оешмасында баш инженер булып эшләп, пенсиягә чыктым. Сез исә язучы. Моны сез язарга тиеш. Безнең очрашу болай гына түгел ул. Ходай белә ул мине кем янына китергәнен...*

*Абзый чыгып китте, һушка килә алмый озак утырдым ул кичне бүлмәмдә.*

*Шул көннән соң Марат абый ара-тирә яныма кергәләп йөрде. Кергән саен бер хәбәр: «Әниебез үлде... (Рабига апайның әнисе Хәлимә абыстайны Әхмәтсафа Дәүләтъяровның ике улы Марат белән Марлес «әни» дип йөрткәннәр), Биби апай вафат (бусы Рабига апайның бертуган апасы). Берсендә:*

*— Соңга калабыз, Факил әфәнде, әсәрне башларга иде бит. Башланган эш — беткән эш...*

*— Сез мине бу әсәрне язарга сәләтле дип уйлыйсыз инде, әйеме? Шулкадәр ышанып әйтәсез, әллә...*

*— Әйе, Сез генә язарга тиеш бу әсәрне.*

*— Соң бит минем Каргалыда...*

*— Булабыз. Җыенызыз, киләсе атнада Казаннан улым килә, машинасы белән безне Каргалыга алып бара. Бер атна вакыт җитәр бит?*

*Иҗат гомеремнең ун еллык дәверен үз эченә алган «эпопея» шулай башланды...*

*...Колагымда Сакмар суы шавы. Күзләрем ком астындагы көл-күмер катламында. Биек алабута арасындагы бормалы сукмактан әкрен генә өскә күтәреләм. Яр өстендә утырган Каргалыда кемнәр эзен табармын икән? Гомумән, ни дә булса табармынмы?*

*Өстән Марат аганың ачык тавышы ишетелде:*

*— Без җыелышып беттек инде. Сезне көтәбез...*

# Беренче китап



# САКМАР ЕГЕТЕ

Ком бураны, ком бураны,
Оренбурның урамы...

*(Халык җырыннан)*

## I

Күңелгә илаһи моң, тәнгә дәрман бирүче язгы тымызык иртә иде бу. Дөнья якты нурга төренгән. Җанда гамь кайный. Иксез-чиксез галәмнән иләс төсләр агыла.

Кояш таң шәфәгын тибрәндереп алган беренче мәлдә үк чыр-чу килә башлаган кошлар белән уянып, иртә намазына хәзерләнә башлаган иде Мостафа. Кемнедер уятмаска теләгәндәй, сак кына атлап йөрсә дә, бу бары күңелле алдану кебек кенә, чөнки яшь хатыны Шәмсия тагын да өлгеррәк: моны ул йокыдан уянганда ук сизеп, тоеп алды — хатыны баш төртеп яткан ястык почмагыннан салкынлык бөркелеп торган шикелле. Әйе, Шәмсия әллә кайчан аяк өстендә икән шул, казанда су шаулый, комганга җылы су салынгандыр — сары җиз ләгән эчендә вәкарь рәвештә борынын өскә чөеп яктырып утыручы комган җәнаплары хуҗа кешенең тәһарәт ала башлавын көтә иде.

Өй хуҗасы, таң яктысы җәелә башлаганда укылган иртәнге намаздан соң, ихата эчендә әвәрә килеп алды, аннан еллар дәвамында күнегелгән гадәт үзенекен итте: чәй вакыты җиткәнен сиземләп, ак өйгә керергә дип, шактый биек болдыр баскычыннан күтәрелә башлаган иде, нindидер сихри көч туктатып, ирексездән янбакча ягына борылып карады.

— Бәрәкалла! — диде ул, гаять сөенечле мизгелдән сабырлыгын җуя төшеп. Хикмәт дисәң дә хикмәт! Гәүдәсе җиңеләеп калды, күңел түрен айкап, актарып нидер яндырып үтте, җанын яшь чактагыча ашкыну биләп алды: янбакчадагы алмагачлар шау чәчәккә күмелгән, әйтерсең кемдер шаярып бакчаны бер төн эчендә ак өрфия белән япмалап алган да, хәзер посып кына ир уртасына җитеп килүче басынкы холыклы хуҗаның бу хәлне күреп, нәкъ шушы рәвешчә әйтелгән «бәрәкалла» дигән аптырау катыш соклanулы сүзен ишетүдән тәм-ләззәт алып, үрсәләнеп-үсенеп торадыр сыман.

Бу аклыкны, матурлыкны сөйләп, аңлатып кына булмас

иде. Мостафа өй ишеген ачарга ниятләгән җиреннән туктап, янә бакча ягына караш ташлады, шушы якты иртә, аклыкка төренеп, күпереп-кайнап утырган алмагачлар аның талымлы җанын кузгатып, ымсындырып җибәрде, моңарчы күргән, кичергән барлык борчулары, кайгы-хәсрәтләр кул белән алып ташлаган кебек юкка чыкты. Карашы көзгедәй актырып аккан Сакмар өсләтеп йөгереп узды. Аларның өйләре Сакмар очында, тар урамны кисеп чыгуга — елга яры. Биек ярдан төшүгә, дөнья яралганнан бирле шулай дуамалланып, уенчаклап агучы Сакмар. Шушы урынга нигез корган акыл иясе — киләчәккә карап эш йөртә белгән Дәүләтъяр бабасын һәр намаз саен догадан калдырмый Мостафа.

Каршы яктагы әрәмә, аның артында ук яңа борын төртеп чыккан бәбкәләрен саклап, теләсә нинди җан иясенә кинәт ташланырга әзер ата каз шикелле мәгърур хәлдә торучы урман, урман артында еракта — күк түренә барып тоташкан зәңгәрсу киңлекләр. Ул чиксезлекләрне маңгай күзе белән иңләп бетермәле түгел, сәүдә эшләренә керешеп, күпме җирләр, илләр гизде, әмма җир читенә түгел, ил читенә дә барып чыга алганы юк. Булган Каргалыда олуг затлар, тарих итеп сөйләрлек мәртәбәле сәяхләр! Исмәгыйль баба, утыз өч ел буе илләр гизеп, дөнья айкап кайткан илгизәр җан үзе генә дә ни тора!

Шау чәчәктә оеп утырган алмагачларга кабат күз төшерде. Күз алмас дәрәҗәдә гүзәллек ташый иде акка төренгән алмагачлардан. Тыныч иртәгә, ил-төякнең кабатланмас бизәкле манзарасына адарынып шактый торды ул.

Рәхәт чигешле хәләтеннән айнып китеп, Мостафа алга омтылды. Иреннәренә тибеп чыккан дымсулыкны иртәнге җил ялмап алдымы, кипшенгән ирене чатнап, алдагы көннәрдә җил-кояш ашап ясалган җәрәхәте әрнеп, үзен сиздереп куйды. Моңа игътибар итеп тормады инде ул. «Җүләр баш, бүкәндәй күпме торырга була»,— дип, эчтән үз-үзен битәрләп, өйгә үтте, йоклап яткан балаларын уятмаска тырышып, әмма нык, икеләнергә урын калдырмаслык итеп, Шәмсиягә эндәште:

— Кая, карчык, җете төстә, кирәкмәгәнгә уралып йөргән чүпрәгең юкмы? Җәһәт кенә табып бир әле... һм...— Теле кибеп, тәненә ут йөгерде.

Хатын-кыз да булсын, төпченми-нитми кушканны үтәп тә куйсын ди. Шәмсия ел торып, Мостафаның болай каударланып, бәргәләнүен күрмәгән чибәр хатын, таң калып, беренче мәртәбә иренә тутырып карады, бу караш шундый гаҗәпсенүле иде, хәтта күз сирпеп алган мәлдә озын керфекләре маңгайга ук сикерешеп, сызылып киткән кашларын сыйпап төштеләр кебек.

— Нинди җете төс ул тагын? Нинди чүпрәк? — диде ул, гаҗәпләнүдән тач беркатлы сабыйга әйләнеп.

Мостафа, шуны да аңламыйсың дигәндәй, тавышын күтәрә төште.

— И-и Алла колы, кызыл-мызыл чүпрәк бетмәгәндер ләбаса!

— Кызыл? — дип янә кайтарып сорады хатын.

— Кызыл булгач кызыл! Яшел дә, зәңгәр дә түгел бит инде! — диде сабырлыгын тәмам җуйган Мостафа һәм, бакча як тәрәзәнең чигүле пәрдәсен күтәреп, Шәмсиягә ым какты, күр, янәсе, әллә һаман да аңламый изаланасыңмы, Хода бәндәсе.

Шәмсия, әсәренеп, тәрәзәгә сарылды, зур кара күзләрен керфек арасына яшерергә өлгермәде, әллә кайдан, тирәннән үк:

— Алмагачлар... — дигән иңрәү ишетелде.

Мостафа өчен серле һәм көтелмәгән иде бу аһылдау. Күкләрне дер калтыратып, бөтен тереклекне өнсез калдырып нindидер гайре табигый затның нәгъръә оруы шикелле тоелды әлеге авазлар.

Хатын ашкынулы хәрәкәт белән пәрдәне умырып тотып, йөзенә каплады. Тәрәз пыяласына бөркелгән уңайга кире кайтып бүлмәне тутырган сулкылдау авазыннан Мостафа үзе дә телсез калып, нишләргә белми тора иде.

Кыланмышын килештермичә, хатын тәрәз төбеннән читкәрәк китте һәм сагышлы тавыш белән телгә килде:

— Ул елны да шушындый матур килгән иде яз... Алмагачлар шау чәчәктә иде, катыкка манчып алган кебек. Ул кошларның сайраулары — зиһеннәрне ала торган иде. Хәерлегә булсын инде...

Мостафа кисәк үрелеп, пәрдәне тарткалап, тәрәзәне томалап ук куйды. Шәмсиянең: «Ул елны да», — дип сүз башлавы юкка түгел. Беренче ирен, унбишенче елны сугышка китеп, эзсез югалган Фәтхулланы искә төшереп аһылдый, сызлана иде яшь хатынның бәгыре.

— Күз тимәсен, дим... Чүпрәк бәйләп куярга кирәк... Бигрәк кеше күзенә чекерәеп кереп торалар... — дип, Мостафа бәрелә-сугыла ишегалдына чыгып китте. Бүгенге иртә, бөтен дөньясы һич кенә дә баягы кебек нурлы, якты тоелмый иде инде аңа...

Шәмсия, шушы халәтеннән аерылып бетмәгән хәлдә, күңелендә нindидер шом бар сыман, ире артыннан иярде.

— Сиңа әйтәм, — диде ул, зур сер ачкандай. — Бүген таң ике тапкыр атты бит... Нәрсәгә юрарга да белмәссең... Саташып атты таң, саташып...

— Таң саташмый, бәндә саташа. Һем-һем... Вәлкәй хаҗи азанны дөрес әйтмәде. Мин сизеп алдым аны, шуңа иртә намазына үз вакытында тордым.

— Гөнаһлы булган икән Вәлкәй...— Хатынның тавышында сизелер-сизелмәс сөенеч чагылып китте.— Алла каршында да гөнаһ бу, бәндә каршында да, име?

— Ансын бер Ходай белә, аны узып сүләшер хәлем юк. Актүбә ягында кызыллар кыштан калган кибәннәргә ут төрткәннәр. Шул да башын бутагандыр. Шайтан таңы бу. Япякты шәфәкъ уйнап алды бермәлне офыкта. Тәрәзәгә күз төшеп, үзем дә ялгышып сикереп торган идем. Әтәч кычкырмагач, шик төште күңелгә.

— Әтәчкә карап ятсаң...— Шәмсия Мостафаның бу сүзләрен уенга алды.

— Әтәч кычкырмый, таң атмый. Вакыты җитмичә кычкырып, дөньяны уятырга Вәлкәй хаҗи түгел лә ул. Искә төшкәндә әйтим, бүген Әхмәтсафа кайтып керергә тиеш, бу әтәчне суярга кирәк. Йончыгандыр бала. Әтәч, мәхлук, үзен көн тугач суясыларын белсә, таңны аттырмас иде дә...— Аның соңгы сүзләрен Шәмсия ишетмәде инде, хатын йөгереп диярлек өйгә кереп бара иде...

Мостафаны моңсу уйлар биләп алды.

...Ир-ат кешегә тол калырга язмасын икән. Җир җимертеп дөнья көткән чакта, бер өер бала-чага белән ялгыз калуның ни-нәрсә икәнен үз башына төшкән кеше генә белә. Гомер иткән хатыны Маһинур кинәт вафат булгач, Мостафа кая килеп бәрелергә белмәде. Балигъ булмаган биш бала: дүрт улы һәм бер кызын кочаклап япа-ялгыз калды да куйды шул. Туган-тумача, күрше-күлән баштагы көннәрдә кайгысын күтәрешкән булып йөрсәләр дә, һәркемнең үз мәшәкате, үз дөньясы, тора-бара хәлгә кереп йөрүчеләр сирәгәя башлады, ә аннары гел беттегә чут. Җитмәсә, сугыш бара. Халык өстенә кара хәсрәт булып ишелгән герман сугышының иге-чиге юктыр сыман иде. Хәер, бер генә яу да халыкка куаныч китерми анысы, мәгәр шунысын да белә Мостафа — сугыштан кемнәрдер кесә калынайта һәм, шиксез, бу кемнәрдер дигән кемсәләр илбашы-патшалар үзләре үк. Дөрестерме, юктырмы, Мифтах хәлфә әйтә, бер дә сугыш алып бармаган илнең патшасын сантыйга чутлыйлар икән. Шулаен шулайдыр, әмма сугышка кызмаган илдә яшәүләре оҗмахка тиң бит. Иле тыныч, казнасы мул, халкы бай — тагын ни кирәк адәм баласына?! Халыкның холкы сәер аның. Рәхәт тормыштан тиз туя — әүвәл үзара ызгыша башлыйлар, аннан патшасына каршы күтәрелә. Коткы салучылары табыла аның. Югыйсә ил-көннәрнең иминлегеннән кадерлерәк, кыйммәтрәк ни бар дөньяда?! Хәерле булсын, патшаның сугыш дип зиһене томаланган, халыкны ут эченә куа тора. Үзенең кесәсе дә шактый калынайгандыр, яраннарының әйтеп торасы да юк, акча исе килмәсә, патшага ешынып

та йөрмиләр алар. Тамагын туйдырмасаң, дуракмыни ул яран булып йөрергә! Башка мәмләкәт патшалары да өлешсез калмыйдыр, һәркайсы: «Җиңгәнче сугышабыз!» — дип лаф орган була әнә. «Бирән нәфесләребез туйганчы халыкның канын түгәбез», — дигән сүзләре инде бу, безнең телгә күчерсәң. Шулаен шулайдыр да, сугышның бер дә туктарга исәбе юк. Асыл егетләр китә тора, яу кырында югала баралар. Исәпләсәң, Каргалының күпме сөлектәй ир-егетләрен йотты инде бу сугыш.

Тол калдым дип, күпме үрсәләнмә, дөнья көтүдән туктап калып булмый: балаларны аякка бастырып, кеше итәргә кирәк. Дәүләтъярныкылар көчле нәсел, тармаклы нәсел, ил өстенә нинди генә афәтләр килмәгәндер дә, башларданниләр генә кичмәгәндер. Нәсел исән, нигез нык, шөкер Ходайга. Һәр ир — гаилә башы үзенең нәсел терәге икәнен онытмаска тиеш, яшәгән дәверендә нәселен бер башка күтәреп куюга өлгәшергә тиеш дип уйлый Мостафа. Шулай булмаса, яшәүнең ни мәгънәсе, ни яме бар! Үзеңнән соң җиргә нык басып яши алырлык, кодрәтле, денле-иманлы буын калсын! Менә ни өчен яши ул дөньялыкта. Маһинурның вафат булуы гына һушны-зиһенне алып куйды менә. Малайларның иң зурысы Гомәрханга — унҗиде яшь. Аның өчен борчылмаска да булыр иде, үз көнен үзе көтәрлек зиһенле егет булып үсә. Хезмәтнең ни-нәрсә икәнен әйбәт чамалый, хәләл икмәкне маңгай тире түгеп кенә табып булганын белеп, эштә чыныгып үскән бала ул. Госманга — ундүрт яшь, монысы, мөгаен, Оренбурдагы Гомәр агайга охшап, укымышлы кеше булып чыгар. Белемгә омтыла, хисләнүчән бала. Әнкәсенең вафатын да иң авыр кичерүче, шушы үз эченә бикләнеп йөрергә яраткан улы булмады микән?.. Унике яшьлек Әхмәтсафа барсыннан да аерылып тора. Җебеп торганны бер дә яратмый, ни кушсаң, шуны ялт итеп эшләп куя, әткәсенең кул арасына керә башлавына Мостафаның үзенә караганда ныграк та сөенә бугай әле. Яшенә караганда олырак күренә, ялгызы калып уйланып утырырга ярата. Уйларыннан аерсалар, нәкъ өлкәннәрчә авыр сулап куя да кушкан йомышны үтәргә йөгерә. Ә сигез яшьлек Әхмәтханга күз-колак булу кирәк тек кирәк. Сәрсән бала, җитмәгән җире юк, көн эчендә кузгатмаган нәрсәсе калмый, абыйлары белән шаяра башласа тыярмын димә, аларны җәфалап бетерә. Бердәнбер кыз — иркәләнү-сөелүдән туймый торган өч яшьлек Бибиҗамал, шомырт кара күзле, ут борчасы шикелле терчә кызы исә Мостафаның кайгылы-хәсрәтле көннәрендә иң олы юанычы, шатлыгы, куанычы иде. Дөнья китереп кысты, берни эшләр хәл юк, шушы балаларга үги инәй алып кайтырга кирәк булып чыкты бит менә...

Каргалы борын заманнан килгән гореф-гадәтләрдән аерылмый. Элек-электән ирләр сәүдә эшендә, патша гаскәрендә казак хезмәтен үтәп гомер уткәргәннәр. Йортның нурын саклау, хуҗалык алып бару хатын-кызлар җилкәсенә өелеп калган. Шуңа күрә Каргалы хатыннары ир хакын хакласалар да, китап кушканча ук гомер буе иргә буйсынып, басылып яшәмәделәр. Алар хөрлеккә омтылучан, айт иткәнгә, тайт диеп торучылары сирәк. Авылда тол калган ялгыз бичәләр булса да, алар шушы хәлләрен артыграк күрәләр: биш бала өстенә килергә ашкынып, ясканып йөрүче юк иде. Мостафа, язмышына күнеп, сабыр итәргә булды. «Язганы чыкмый калмас, өзми-куймый бичәләргә яучы җибәреп, кеше көлкесенә калганчы, көннәр үтә торсын, балалар үсә торсын, шул арада, Ходайның рәхмәте киң, бер насыйбы да чыгып куяр»,— дип, үзен тынычландырып яши башлады.

Шушы уйдан аның җаны тынычланып калды, күңелен юк-бар шаукымнар алгысытмый иде инде.Менә шулай тыныч кына яшәп яткан көнендә дөньясы тагын асты өскә килде. Сәбәпчесе: Шәмсия җибәрттергән хәбәр иде. «Мостафа агай эндәшсә, риза булырыем, дип әйтә Шәмсия»,— диде Тайфә карчык, беркөнне истә юкта иртүк өенә килеп кереп. Карчык, чигенергә һич тә исәбе юклыгын сиздергәндәй, соңгы араларда яучылардан туеп, алардан да, кабат өйләнү ниятеннән дә бөтенләй ваз кичкән Мостафаны озаклап үгетләргә җыенган шикелле, җиңнәрен сызгана-сызгана түргә атлады.

Өй эчен тынлык биләп алды. Иң беренче Тайфә карчыкка җан иңде. Йөзеннән шөбһәле уйлар йөгерешеп үтте. Әйтерсең лә янына килеп ун туптан атканда да колак яфрагын селкетер тоелмаган шушы Мостафа атлы адәм гөлт итеп кабынып китәр һәм әллә нинди сүзләр әйтеп, карчыкны пыр туздырып өеннән сөреп чыгарыр иде. Тайфә карчык көтелмәгән уйдан куырылып куйды. Югыйсә Аллаһ шаһит, ул балалар хакын гына хаклап йөри. Әгәренки киресенчә булса, инде керә-керешкә үк ишекне ачып, болдырга аяк басуга, җир ярылып, эһ диярgә өлгергәнче, ул җәһәннәм чокырына төшеп китәр иде. Хәтта ки япун сугышында һәлак булган изге җанлы картының рухына кылынасы бихисап догаларын кылып бетерә алмыйча казага калдырып, бер гаепсез, изге юлда дип әйтерлек йөргән җирдән юкка чыгар, зәрзирбизәр булыр иде.

Шөкер, Мостафа күтәрелеп бәрелмәде. Сүзсез генә иртәнге чәйдән соң җыештырырга өлгермәгән сәке почмагындагы ашъяулыкны яртылаш әйләндереп каплады да түрдәге зур мендәрләрнең берсенә үрелде. Сизгер карчык гадәт-йола буенча һәр кергән йортта була торган бу күренешне дәш-

ми-тынмый гына карап тора алмады, Мостафаның җиңеннән сак кына тарта төшеп, туктатасы итте:

— Туган, утырып, озаклап сүләшәсем юк та...

Мостафа, ниһаять, телгә килде, карчыкны ай-ваена карамый утырырга күндерде.

— Аптырашта калдырдың, Тайфә түтекәем, әйдә, утыр әле, аңышып бетеп кенә булмый бит...

— Аягөсте генә дә сүләшер сүз түгел шул, наныем,— диде карчык, сөенечен тышка чыгарып түгәргә ашыкмыйча.— Әйдә алайса, бер дога кылыйк,— дип, мендәрнең читенә генә артын терәп утырды да ике кулын кушырып битенә якын китерде. «Ил-көннәр имин, дөньялар мул, ниятләр гамәлгә ашсын, Раббым»,— дип кычкырып әйтте дә, пышылдауга күчеп, җиренә җиткереп, аерым бер чырышлык һәм ләззәт белән дога кылды. Мостафа янына ул чын күңелдән, ашкынып килеп керде, морадына иреште дә кебек әнә.

— Ялгыз дөнья алып барулары-ы...— дип суздьі ул, эш пешкәнгә санап.— Ир-ат кеше хатын-кызсыз гүпчим яши алмый ул. Мәгәр алтын баганакае, дөньякайларның тоткасы булган иреннән калып сыңар канат белән балаларны аякка бастыру ялгыз хатыннарга да җиңел түгел, Мостафа энем. Картымның япун җәдрәсе тиеп шәһит киткәненә ун ел, ник бер минут исемнән чыксын менә, ышансаң. Әле ярый, уллары тәүфыйклы, тулыклы булдылар. «Инәй, ни эш бар?» — дип кенә торалар инде җаныкайларым. Картыма охшап, эре сөякле, буй-сынлы булып үсеп, алыптай җегетләр булып киләләр, боерган булса.— Карчык, ни өчен килгәнен исенә төшергәндәй, утырган җиреннән Мостафага табан авышты: — Балалар күзгә-башка чалынмый...

Мостафа авыр сулап куйды. Көттереп кенә:

— Бәләкәчләре йоклый, зурлары дөнья куа,— диде.

Тайфә карчык ирнең сүзен тыңлап бетермәстән, үзенекен тезә башлады:

— Шәмсиянең дә Фәтхулласы суга төшкәндәй юкка чыкты бит. Бичараның, ярман сугышыннан бер хаты килде дә шуның белән Аллаһу әкбәр. Шәһит җаны оҗмах ишекләрен иң беренчеләрдән булып ачып керсен, кылган догаларыбыз туп-туры рухына җитешеп, безне дә көләч йөзләре белән оҗмах түрләренә әйдәкләп алып керсә иде. Бикколга, яраланып, бер солдат кайткан икән, шул килеп әйткән, Фәтхулла белән сугышка бергә кердек, икебезгә бер мылтык бирделәр, мылтык андае, котелок миндәе, агылыйга-тагылый сыман бергәләп чабып барадырыек ярманга каршы, перәме аяк астына туп төшеп шартлады, дип әйтә ди. Шуннан соң бер нәрсә дә хәтерләмим, мине шул кәтилүк кенә саклап калган, мәхлук, тишкәләнеп беткән, үзем белән бергә

табиблар гуспителгә илтеп салганнар бер чокырдан табып алып, дип әйтә икән. Ул сугышта исән калучылар аз булган, Фәтхулла да үлгәндер, яралы-мазар булса, бергә булган булырыек, дип әйтә ди. Савыгып чыккач, сораштырдым — белүче булмады, урыны җәннәттә булсын, ул үлеп калгандыр, дип, шушы хәбәрен әйтеп киткән. Биккол кешесе килеп киткәнгә дә ел үтеп бара. Шәмсияне беләсең, Сакмар очында үз йортлары белән тора. Кызның әти-әнисе ниндидер кизүдән вафат булгач, Фәтхулла йортка гына кергән иде. Үзе — яшь, чип-чибәр, ул эшкә дисеңме, ул төскә дисеңме, илгә гайбәт-мазар чыкмаган. Яшерен-батырын түгел, хатынның тәтесен тарткалап караучылар күп булды. Ни уйлап йөри микән бу бала дип, үзем дә хафага калган чакларым барые. Шәмсия кичә чакыртып алды үзенең янына. Озаклап серләшеп, сөйләшеп утыргач, эчендәге иң соңгы серен ачып салды: «Әбекәем, ялгызыма бик кыен, утыз яшькә кадәр яшәдем якты дөньяда, бер рәхәт күрмәдем. Мостафа агайга сүз тишеп карасак, ул үзенә хәләллеккә алмас микән, ди җаныкаем. Михнәтенә дә, рәхәтенә дә түзәрмен, бер дә башка кешегә күңелем ятмый»,— дип әйтте. Инде, Мостафа туган, миннән эш калмады, соңгы сүз синеке,— дип, Тайфә карчык тынып калды.

Аптырашып утырудан файда юк. Мостафа — әле генә кырыкның өстенә чыккан, типсә тимер өзәрлек, басса бакыр сытарлык ир. Ялгыз хатынның күңеле ятып, хәбәр салган икән, ни гаебе бар?! Үзең мәңге ул якка аяк атлап бармаячак идең бит, Мостафа, уйла, уйла! Шәмсиягә үрелеп азапланучылар аз булмады булуын, Мостафа җир белән күк арасында йөрүчеләрдән түгел, барсын да ишетеп, күреп яши — чибәркәй нык холыклы булды, илгә-көнгә яманатын чыгармады. Яшәргә дип казгана, көткән дөньясын таратмаска җанфәрманга тырыша иде. Күпме уйларга була: балаларга әни кирәк. Бигрәк тә Бибиҗамал белән Әхмәтханга әниләренең мәңгелек йортка киткәнен аңлатуы кыен. Көн-таң атса: «Инәй бүген кайтамы?» — дип җелеккә төшәләр. Шушы сораулары йөзгә сары сулар булып ята инде...

Мостафа тәвәккәлләргә булды. Әмма нигәдер Тайфә карчыктан кыенсына, авызын чак кына ачып:

— Кайчан? Кһм-хм,— дип кенә аваз салды.

Тайфә карчык аның ни әйтергә теләгәнен ярты сүзеннән аңлап, туры караган кояштан нурга тулышкан Сакмар кебек яктырып китте.

...Тайфә карчык әйләнеп кайтканчы, Шәмсия ярым караңгы өй эчендә, уйлар камалышында ялгызы бәргәләнде. Хатынның тәвәккәлләп Мостафага атап яучы җибәрүенең

башкалар белеп җиткермәгән сере бар иде шул. Бу хакта Шәмсия Тайфә карчыкка да чишелеп тормады.

Соңгы вакытларда аңа азанчы Вәлкәй хаҗи каныга башлады. Яучы-мазар аша түгел, туп-туры өенә килеп, үзенә икенче хатынлыкка сорап тинтерәтә, карт шайтан. Олы хатыныннан өч баласы бар, өлкәннәре Шәмсиядән ун яшькә кечерәк булса булыр. Шушы карт йолкыш, бер хатынын ныклап тота алмыйча, көн туса җәнҗал чыгарудан бушамаган Вәлкәй мөртәт бәгыренә төшә башлагач, яшь хатын берничә көн аягөсте исәнгерәп йөргәннән соң, өч-дүрт төн түшәктә әүмәкләп чыккач һәм түшәге генә түгел, чәч толымнарына кадәр күз яшьләренә манчылып, сыгып алмалы булгач, авылга сүз-мазар таралганчы дип, чыннан да моңарчы читтән генә күз салгалаган, төскә-биткә һич тә Фәтхулладан ким булмаган Мостафага сүз ирештерергә карар кылды.

Ике толның кушылуын бөтен авыл хуплады диярлек. Тик Вәлкәй хаҗи гына каядыр барырга җыенып ишегалдында ат җигеп маташкан Мостафаны күреп алгач, ямьле көннең төсен җибәрде: хуҗаның үзеннән битәр гайрәтле юргасын сискәндереп урам як киртәсенә таягы белән җенләнеп суга-бәрә, күзләрен акайтып авызыннан төкерек чәчте:

— Кеше өлешенә кердең, Мочтай, өлешкә кердең! Мәчеттән килеп хәер-фатыйха алмадың. Никахыңны укыган Мифтах хәлфәгә бәддога ирешсен, кул арты белән дога кылдым үзенә. Их... ялгыштың, Мочтай, ялгыштың... өлешкә кердең... Мәңге рәхәт күрмә, Аллаһның...— дип каһәрли-сүгенә мәчет ягына китеп барган иде.

Бу хакта Шәмсиягә әйтеп, аны аптыратып йөртәсе килмәде, Вәлкәй хаҗи хакында аңа яшь бичәсе сүз арасында сак кына үзе дә сиздереп алган иде, бу вакыйга ничек кисәк булса, шулай тиз онытылды да. Тик шунсы бар — Шәмсия Вәлкәйне: «Карт шайтан, карт иблис»,— дип өзми-куймый битәрләсә дә, хаҗи Мостафадан ике-өч яшькә генә олырак, һич тә алай бетәшкән карт түгел иде...

...Хатынының күптән шәһит саналган Фәтхулланы искә алып, җон-май түгеп, елап алуы Мостафаны четерекле хәлгә куйды. Әйтерсең кемдер аның тез астына сиздерерлек сукты. Хәзер ир, шушы хәлдән соң, берни дә булмаган кебек йөрергә тиеш ди. Нинди йөрү булсын, мәрәләү генә инде бу, теге чактагы шикелле җир җимертеп, ашкынып йөрүләр, айһай, яңадан кабатланырмы?.. Ул ни эшләргә белми кызу адымнар белән ишегалдын урап чыкты. Бераз исенә килгәч, кулларына карап хәйран калды: каян хасил булгандыр, юньләп аңышмады, әллә шул арада Шәмсия кулына тоттырган, әллә каяндыр үзе табып алган, әмма шунсы хак —

аның кулында вак-вак теленгән җете кызыл тасмалар пәйда булган иде.

Мостафа, капканы бәйләгән озын сүс бауны кабалана-кабалана чишеп, бакча эченә үтте һәм рәхәт аклыкка оеп утырган алмагач ботакларына кызыл тасмалар бәйли башлады. Бу эшне ул ихтыярсыз, ниндидер сөенеч-шатлык хисләрен кичерми башкарды. Иртән башка килгән уй-фикерләр, җанын сафлыкка тиендергән иләс хисләр җилгә очып, таралып беткән иде инде. «Дөрес әйткәннәр картлар,— дип уйлады ул, эше белән мавыга төшеп бераз тынычлангач,— ике тол кушылса, кич йокларга икәү яталар, иртән йокыдан дүртәү уяналар, имеш. Мин һаман Маһинурымны уйлап саргаям, Шәмсия үзенең беренче ире — Фәтхулла дип тилмерә, күрәсең».

Дөнья дигәнең бер дә тыныч түгел шул. Герман сугышы гына җитмәгән, патша галиҗәнаплары үз тәхетеннән баш тартты да куйды бит. Монысына тагын ни дияргә? Тәхет кадәр тәхеттән үз теләге белән ваз кичкән патша хәзрәтләрен әйтерием инде, шул да булдымы патша, шул да булдымы гамәл? Бераз гына да башы эшләмәде микән бахырның? Ул яраннары, вәзирләре ни-нәрсә карагандыр, ни-нәрсә акыл биргәндер Микулайга. Аларны шул патшаның башы эшләми торганда, акыл бирү өчен, илне бәла-казалардан саклау өчен тоталар түгелме соң? Патша китте дип, тәхет буш тормас, билгеле. Гомер бакый тарткалаш бара шул тәхет тирәсендә. Тарткалаш кынамы соң?! Сугыш бара илдә. Ата улны, инә кызны белми, туган туганга, мөселман мөселманга кылыч күтәрә. Ул Лилин дигәненә ни җитмәгәндер, халыкны болгатырга. Халыкны аны болгатып кына җибәр, аннан ник болгатканыңа үкенерсең. Үзе нимеч шпиуны икән. Бер митингәдә Зәки Вәлиди шулай сөйләп торган ди. Анысы башкортларның патшасы булып куйды тагын. Исең китәр, башкортлар патшасына тәхет кирәк дип, аның гаскәренә меңәрләп-меңәрләп язылган безнең татар җан-фәрманга кан коя. Вәлидинең: «Революция — безнең өчен көтеп алганнан да зур бүләк. Әгәр авыз ачып калсак, ул бүләктән коры калачакбыз, әйдә, батыр сугышчылар, гаярь башкортлар, яуга!» — дип бер кычкыруы җиткән, бөтен татар дәррәү сикереп торып, «ур-ра» дип, гел кычкыра-кычкыра, сугышка да кереп киткәннәр. Менә сиңа мә, татарлардан торган башкорт гаскәре шул була инде. Борын-борыннан тәхет тынгылык бирмәгән инде бер төрле холыклы кешеләргә. Ханнар-патшалар вафатлары алдыннан тәхетне варисларына васыять итеп калдырган, аңа исә әллә нинди юлларын табып, алдан ук хәстәрен күреп йөргән хыянәтче менеп утырган.

«Дөньядагы бөтен тәхетләр телгә килеп, үзләре шаһит булган хыянәтләр хакында хәбәр итсәләр, тарихны өр-яңадан язарга туры килер иде», — ди Мифтах хәлфә. Лилин пайтәхетне Мәскәүгә күчереп карады каравын, соң анда да шул бер тәхет инде. Тәхет өчен ызгыш-талаш оештыручы иблис үзләреннән алда күчеп килгәндер Мәскәвенә. Айга менеп утырсаң да, тәхеттән калмый ул, иблис. Ходай ни язган. Менә татарларның патшалары бар микән, әллә өлгермәделәр микән әле патшалы булырга? Борынгы дәвердә куәтле патшалары булган татарның, булган. Тик хыянәт һәркайсының башына җитеп килгән. Шул хыянәтләр аркасында патшасыз да, тәхетсез дә, илсез дә калган инде ул татар. Тагын берәрсе килеп чыгып, үзен татарның патшасы дип игълан итәр микән, Ходаем! Аңа бәләкәй генә булса да тәхет бирер микән Лилин. Бирсә — шыр дивана була да инде. Татардагы хөсетлек, көнчелек ул бәләкәй патшага эшләргә ирек бирерме? Бер дә ышанасы килми. Тәхет өчен бер-берсенең бугазын чәйнәргә әзер безнең халык. Инде шушы афәтләрдән сакла, Ходаем. Аптыраш, уйласаң. Их Микулай, җүләр Микулай!.. Тәхетне кешегә бирәләр димени, ә?

Узган ел яз көттереп, ялыктырып килде. Һай, авыр да булды инде. Озакка сузылуы гына җитмәде, чәчүгә төшкәч тә, тоташ яңгырлар башланды. Инде туктады дисәң, тагын Сакмар ягыннан болыт күпереп чыга, яңгырдан тәмам йончыган дөньяны янә суык тамчылар каезлый башлый. Яңгырлар тынды дип, иркенләп сулыш алып, эшкә тотынырга өлгермәделәр, моңарчы сүрелеп торган яу тагын көчәеп китеп, авылга гаскәрләр килеп тулды. Мәхшәр менә кайда икән ул. Гаскәрләр үзләре дә ни өчен, кем өчен сугышканнарын белеп бетермиләр. Һәркайсы халык, җир, ирек дип сөйли. Тик һәркайсы үз каланчасыннан торып халыкны үгетли, үз ягына аударырга тырыша, агай. Әгәр гел митингәләргә йөреп, телмәрчеләрне тыңлап көн уздырсаң, валлаһи дим, аңнар авышып, дин, милләт, иман кебек изге төшенчәләр, язгы җебелдек балчыкка уралган утын көле сыман, төсләрен җуя башларлар иде. Һәр төркемнең холкы-фигыле, кыланмышлары аеры булса да, сүзләре-шигарьләре — бер. Бу сүзләр аң-зиһеннәрне шулкадәр саташтырып бетерделәр: аларны, әүвәл Каргалы елгасына, аннан Сакмарга агып төшеп, ахырда, Җаек суы дулкыннары арасында тәмамсы юкка чыккан болганчык язгы ерым сулары белән генә чагыштырып булыр иде кебек — төрле авыздан ишетелгән бер үк сүзләр туйдырып бетерде. Халык җир, иген язмышы турында уйлый, болар сүз сөйлиләр. Дутовның ак казаклары халыкны тинтерәтә, аларны кызыл партизаннар дигән ниндидер корама

халык алыштыра. Болары бигрәк тә телчән булып чыктылар. Туктаусыз хөррият, ярлы-ябагай мөселман туганлыгы, берләшү дип такылдыйлар, үзләре шул ук мөселман халкын талыйлар, ир-егетләрен көчләп армиягә куалар. Хуш, инде алары авылдан чыгып китеп, котылдык дисәләр, артларыннан, эзләре суынганны да көтмичә, авылга башкорт гаскәрләре кереп тула. Аларның телендә исә аерымлашу, мохтарият. Ә тыңлый торгач, төшенгәч, мәгънә бер үк — берләшик, аерылганны аю ашар, бүленгәнне бүре ботарлар, имеш.

Җир, ирек алу өчен нәкъ менә Каргалы халкының алар ягына авышуы кирәк икән. Алар табынган иң шәп шигарьләр тормышка ашсын өчен, боларына да шәп, таза ир-егетләр, ашарга азык, киенергә кием, хәтта атларына печән белән фуражга кадәр кирәк һәм моны да Каргалы халкы бирми, кем бирсен?! Үзләре әрсез тагын, халык биргәнне көтеп тормыйлар, ихатага кереп, күзләренә ни чалына, шуны эләктереп алып таялар. Түләү турында сүз дә булу мөмкин түгел, авыз ачсаң, кем булуыңа карамастан, маңгайга пуля утырту белән генә яныйлар. Афәтле булды унсигезенче ел...

Шул уйлар белән бакчада күпме матавыклангандыр, колагына Шәмсиянең:

— Сиңа әйтәм, чәйне өч тапкыр яңарттым, кер инде,— дигән йомшак тавышы ишетелде.

## II

Кабул итү бүлмәсе ишеген мыштым гына ачып, йомшак адымнар белән кереп килүче Сталинны күргәч, сәркатип хатын бөрешеп калды. Ул аны яратмый, шадра һәм, гомумән, гарип кыяфәтле бу адәм күзенә чалынса, йөзенә нәфрәт ташып чыга. Шул ук вакытта ул аннан шүрли дә. Хатынның мондый мөнәсәбәтен Сталин үзе дә сизә, әмма тышка чыгармый, бу юлы да килеп кергән уңайга сәркатипкә көлемсерәүле караш ташлап алган булды, әмма битенә җәелә башлаган якты чаткы тиз арада сүрелеп, аны мәсхәрәле елмаю алыштырды. Сталинның чын йөзе, холкы шушы иде һәм сәркатип хатын аны шундый икейөзле булуы өчен күралмый да инде. Әгәр Сталин сул як стенага күптән түгел генә элеп куелган зур көзгегә карап алса, үзенә ян белән утырган сәркатип хатынның бөтен битен тутырып чабышкан нәфрәт дулкыннарын күрер иде. Тик Сталин көзгегә карарга яратмый иде. Хәер, аның бу хатында бөтенләй кайгысы юк, ник кадалып китми шунда.

Рөхсәт-мазар сорап тормастан, Ленин янына үткәнче янә бер тапкыр әле генә Троцкий белән булган сөйләшүен хәтердән яңартты. «Стратег табылды!» — диде ул, бу юлы

инде чын-чынлап мыскыллы уйларына ирек биреп. Имеш, Куйбышев белән Фрунзе Көнчыгыш фронтта гаять акыллы сәясәт алып барып, Идел-Урал буйларында хәрәкәт иткән каршы көчләрне тиз арада куып таратып бетерәчәкләр; имеш, аларның иң зур уңышы — кичә генә килешмәс күренгән дошман төркемнәрен әкренләп үз якларына аударып, дошманнан дус ясау сәясәтенә ныклап керешүләрендә. Башкортларның Вәлидов хөкүмәте хәзер совет яклы, бөтен Идел-Урал төбәгендә татар егетләрен Кызыл Армиягә мобилизацияләү дә искиткеч шәп бара. Араларында үз инициативалары белән гаскәр җыярга керешкән Усманов кебек сәрдарларның булуы бигрәк тә күңелле хәл, имеш.

Троцкийның, очлы сакалын чөя-чөя канатланып, хәтта хискә үк бирелеп, вакыты белән бөтенләй сакауга әйләнеп бетеп сөйләшүен Сталин башта көлемсерәгән кыяфәттә сабыр гына тыңлап торган иде. Аз гына уңыштан да шулай сөен инде, җә! Никадәр балалык, никадәр беркатлылык бу бәндәдә. Ун ел буе коры җир күрми диңгездә адашып йөзгән моряк та, ярга аяк баскач, бу кадәр үк сөенми торгандыр, ачуым бер килмәгәе. Ахыр чиктә Сталинның сабырлыгы төкәнде, Троцкийның шашына язардай очынуы күңел кайтаргыч дәрәҗәгә җитте, ул моңа чик куярга тиеш иде. Милләтләр халык комиссары тыныч, әмма ярсулы тавыш белән теш арасыннан:

— Бәхетсез романтик! — дип ычкындырды.

Троцкий шып туктап, әңгәмәдәшенең йөзенә карады. Сталинның бите буйлап тәртипсез рәвештә кара күләгәләр чабыша иде.

— Бәхетсез романтиклар, — дип кабатлады янә Сталин. — Бухарин, Рыков икътисадта, сез хәрби эштә шушы романтикадан ерак китә алмыйсыз. Революциядә үгет-нәсихәт, романтика чоры узды. Җиргә төшәргә кирәк. Милләтләр эше бүген иң үзәктә торган мәсьәлә. Әгәр һәркем бу четерекле эшкә уйламый-нитми борын тыга икән, бүгенгә ирешкән азмаз уңышлардан да колак кагачакбыз. Революция һәм милли аерымлануга йөз тоткан сәясәт бер-берсенә сыеша алмый торган, хәтта әйтер идем, дошмани төшенчәләр. Моны аңлап дөрес бәя бирмәсәк һәм милли төбәкләрдә соңгы чорда гөмбә урынына баш калкыта башлаган «инициаторларны» йөгәнләмәсәк, соңыннан утырып еларга туры килмәгәе дим. Турысын әйткәндә, милли сәясәт белән шөгыльләнүче «белеклеләр» күбәйде хәзер... — Сталин, бер авыз ачкач булган булсын инде дигәндәй, тагын бер-ике төртмәле сүз ычкындырмакчы иде, Троцкий күзендә уйнап алган зәһәр очкыннарны күреп, иплерәк тонга күчте. — Милли төбәкләргә кагылышлы һәр гамәлне төптән уйлап, үзара киңәшләшеп эш алып барсак кына отачакбыз.

— Анысы хак. Киңәшле эш таркалмый...— диде Троцкий. Үзенең эчендә ачуы кайнап түгелергә җитеште. «Син, ата иблис, хет бер генә эшеңне башкалар белән уртага салып, киңәшләшеп эшләгәнең бармы? Йә бергәләп кабул ителгән карарны үз файдаңа бормыйча каласыңмы?»

— Һәркем юрганны үз ягына тартса, безнең ясаган адымнарыбыз, иң шәп дигәндә дә, бер урында таптану булып калачак.

Троцкий кабынып китте:

— Мин сезне, кадерле иптәш Сталин, нәкъ шуның өчен чакырдым да инде. Сөйләшергә кирәк...

— Алайса, әңгәмәне болай дәвам итү яхшы булыр. Вәлидовның советлар ягына чыгуы өчен аз тырышмадым мин. Моны комиссариатта эшләүчеләр яхшы белә. Ә инде татарларга килсәк, Вахитов, Солтангалиевләр янына тагын бер калай әтәч — Усмановның өстәлүен һич тә теләмәс идем. Әгәр алар эздән чыксалар, Вәлидов күрсәткәннәр уен гына булып калачак.

— Моның белән дә килешәм. Әмма бер нәрсәне истән чыгарырга ярамый һәм кабатлап әйтәм, бүгенге армиябезнең хәле шундый: барлык фронтларда да авыр йөк — татарлар җилкәсендә. Аеруча пехота, артиллериядә шулай. Кайсы гына фронтны алма, сан ягыннан карасак, гаскәриләрнең күпчелеге — Идел буе татарлары. Алар, һич арттыру түгел, революциянең терәге. Шуңа күрә бүгенге көндә Идел буенда төзелеп бетеп килгән Усманов бригадасы полкларына иптәш Куйбышев белән Фрунзе зур өметләр баглыйлар. Минем уемча, монда бераз гына сабыр итәргә кирәк, бригаданы өстәмә рәвештә корал, башка кирәк-яраклар белән тагын да ныгытсак һәм яшь солдатларны ай-ай ярым хәрби осталыкка өйрәтергә мөмкинлек тудырсак, ышанып әйтәм, Көнчыгыш фронт үзенә йөкләнгән бурычны тулысынча ерып чыга алачак. Усмановка ышанып ялгышмаганбыз, оста оештыручы, зирәк егет икәнлеген эштә раслады. Ул бер генә нәрсәне үтенә: әзерлек эшләре тәмамланмыйча, бригаданы урыныннан кузгатмаска һәм фронтка бары тик тулы составта җибәрү. Яшь комиссарның исәбе — оешмас борын бригаданы таркатуга юл куймау. Мин аны яклыйм. Бездә андый эшкә маһирлар табыла ул.— Троцкий, хәйләкәр елмаеп, Сталинга күз ташлады.— Шулай булганда гына Җаек буйларын тулысынча колчакчылардан һәм калдык-постык казак отрядларыннан арындырып бетерергә мөмкин булачак. Ташкент тирәсендә озакка сузылган сугышлардан соң ял итеп өлгергән Төркстан фронты да хәлләнеп килә. Татбригада сугышка кергән уңайга Төркстан фронтының кайбер берләшмәләре Тургай даласына, ягъни татарларга ярдәм итеп хәрәкәт

итә башласалар, һичшиксез, Көнчыгыш фронт җәйге компанияне уңышлы башкарып чыгачак. Ул вакытта сезнең Көньяк фронтта...

Троцкийның соңгы сүзләре Сталинның йөрәгенә ук булып кадалды. Ул Үзәк Комитет тарафыннан Көньяк фронтка җаваплы итеп билгеләнгән кеше буларак, инде кайчаннан бирле Ворошиловның тулы бер армияне Сарысу янында нәтиҗәсез бет туйдырып яткыруыннан гарык булган иде. Башка реввоенсовет әгъзалары айлар буе фронтта, турыдан-туры гаскәрләр белән идарә итүдә катнашсалар, Сталин берничә мәртәбә Сарысу тирәсенә барып кайту белән чикләнде. Ул чакларда Ворошилов белән үзләренчә гаять уңышлы тактик операцияләр дә үткәреп азапландылар, әмма дошман гаскәрләренә маңгайга-маңгай юнәлдерелгән гади һөҗүм операцияләре меңләгән солдатларны чебен урынына кырдырудан башка бернинди уңыш китермәде. Ворошиловның булдыксызлыгын Сталин эченнән таныса да, реввоенсоветта Троцкий кебек бәндәләр утырганда, ул аны өзгәләүгә юл куймаячак иде. Иң хәлиткеч мәлләрдә кемгә таянырга? Сыналган дусларга — Ворошилов кебекләргә, билгеле. Шуңа күрә Троцкийны кискен рәвештә бүлдерде ул:

— Көньяк фронт үз бурычын артыгы белән үти. Ворошиловка каршы акларның регуляр армиясе сугыша. Көнчыгыш фронттагы, үзегез әйткәнчә, калдык-постык казак бандалары түгел... Димәк, тагын ай-ай ярым вакыт кирәк, дисез, татар полкларына...

— Иптәшләр шундыйрак фикердә. Күптән түгел анда Калинин булып кайтты. Яңа гаскәрләр яхшы тәэсир калдырган. Алдагы операцияләрне планлаштырганда бу факторны исәпкә алырга туры килер.

Сталин, Троцкийдан чыгуга, туры Ленин янына китте. Әгәр Куйбышев үз дигәненә ирешсә, ул чагында... Әйе, Көньяк фронт белән яна бугай Сталин. Бөтен өмет Буденныйның кавалериясендә. Фрунзе — тәҗрибәле хәрби белгеч, ни кыланганын яхшы белә, Көнчыгыш фронтта хәлиткеч җиңүләргә ирешәчәге көн кебек ачык. Троцкий җүләр түгел, дөрес уйлый — революциянең язмышы Көнчыгыш фронтта хәл ителә. Тик революция язмышы гына түгел шул... Бу очракта аның, Сталинның, язмышына да нык сугачак фронтлардагы хәлләр. Аңа болай да теш кайраучылар күп. Фрунзены кулдан ычкындырмаска кирәк, аны ничектер Көньяк фронт белән дә бәйләп куярга иде. Бу вазгыятьтә Көньяк фронтны үз сыртыңда алып чыгарга тырышу ахмаклык булыр иде. Нәкъ шуның аркасында Сталин баш калкыта алмый бит. Очлы сакаллы карт төлке моны да яхшы белә. Әнә ничек астыртын, төче елмаеп карап алды ул Сталинга. Ди-

мәк, бер генә юл кала — Троцкийның планнарын чәлпәрәмә китереп ташларга кирәк...

Ленин кабинетына ул үз-үзенә нык ышанган хәлдә, төпле уй-ният белән кереп китте.

... Ленин шул ук көнне Фрунзега шифрлы телеграмма җибәрде: *«Оренбурның нинди кыен хәлдә калганын беләсезме? Шәһәрне саклаучы тимерьюлчылар бүген миннән ике полк пехота, ике кавалерия, һич булмаса, 1000 пехота һәм берничә эскадрон җибәрүне сорыйлар. Ни эшләмәкче буласыз, сезнең планнар ничек? Тиз арада хәбәр итегез!»* Икенче телеграмма Көньяк фронтка күпсанлы гаскәр җибәрүне таләп итә иде...

Фрунзе ике ут арасында калды. Татбригаданы ашык-пошык фронтка җибәрүнең җинаятькә тиң гамәл икәнен дә белә, шул ук вакытта Ленин фәрманын да үтәми булмый: әгәр алдагы айларда фронтлардагы хәлләр кискенләшсә, аның үзен бу хәлнең гаеплесе итеп күрсәтергә мөмкиннәр иде. Гаепләү өчен сәбәп ансатның да ансаты — белә торып фәрманны үтәмәдең! Бетте-китте, вәссәлам.

Төзелгәндә үк күп шау-шу, тавыш-гауга тудырган татар бригадасын «эш»тә сынап карарга вакыт җитүен сәбәп итеп, Фрунзе май урталарында Усмановка бер полкны ашыгыч рәвештә Оренбурга озатырга фәрман бирде. Усманов беренче мәлдә баш-аягы белән каршы килде. Бригада әле тиешле сугышчан әзерлеккә җитмәгән дип саный иде ул, ашыгып фронтка китүне һәлакәткә тиңли иде. Иң сәере шул — аны моңарчы яклап килгән Фрунзе үзе үк бригаданы таркатуга керешә. Аңлау өчен сәер, бик сәер хәл иде бу... Полк белән бергә, Идел буе татар-укчы бригадасын мең җәфалар чигеп оештырган яшь комиссар Шамил Усманов та фронтка китеп барды. Тылда калган частьлар белән әвәрә килеп ятуга караганда монда кирәгрәк саный үзен Усманов һәм болай уйлап һич тә ялгышмый иде...

...Казаннан пароходка төялеп Сызраньга килгәндә, аннан поезд белән Оренбур ягына кузгалып киткәндә дә, Усманов үзендә гаять зур җаваплылыкны тоеп, хисләренә ирек бирмәгән иде. Юлда вакыт бар, ара-тирә полк составында фронтка баручы артистлар янына гына кереп чыккалый башлады. Аларга карап теләсә никадәр хисләргә бирел, гаепкә алучы юк. Артист халкы кайда да артист булып кала, ике дөнья бер морҗа, уңайлырак урын тапсалар, дөньяларын онытып, ду китереп, репетиция ясый башлыйлар. Җитмәсә, артистлар арасында яшь, чибәр кызлар да бар. Егетләре кызларга егылып гашыйк булып та куйганнар, һәркайсының үз кайгысы — «үз мәгъшукасын» башка чит-ят күзләрдән саклап калу. Ни әйтсәң дә, егетләр дә төшеп калганнардан тү-

гел, кызлар өчен алар арасында гаять зур конкуренция бара, телләре телгә йокмый, авызларыннан кошлар очыралар инде, тыңлап барсаң. Әмма бу хәлләрдән кызык табып йөрергә җай юк, вакыты ул түгел шул.

Шамил Оренбурга якынлашып килүләрен күңеле белән тоеп бара иде, алгы вагоннан паровозга табан үтте һәм, мичкә күмер ташлап мәш килгән кочегарга орынмаска тырышып, иң алга ук килеп басты.

Оренбур... Аның балачагы, үсмер еллары үткән серле кала... Күпме хыялларына канат булды Оренбур, күпме ашкынулар, тетрәнүләр кичергән шәһәр ул. Үсмер чагында радио белән җенләнеп, китап, журналлар актарып никадәр йокысыз төннәр үткәргәнен исенә төшереп, тәненә рәхәт җылылык йөгерде, иреннәренә елмаю кунды. Ыспай, зыялы кыяфәтле, яңа фуражкасы астыннан тыенкы гына чыгып торган бөдрә чәчле бу егеткә елмаю бик килешә иде. Хәрби киеме дә гәүдәсенә ятышып тора. Яшерен-батырын түгел, артист кызлар, ул килеп керсә, бөтенләй әллә нишләп китәләр, ятлаган сүзләрен оныталар, биегәндә ялгыш басып иза чигәләр. Үзләре астан гына комиссарга яндыргыч караш ташлап өлгерәләр. Их, тыныч вакыт булса... Шамил белер иде яшьлекнең кадерен. Аның йөрәге сулкылдап куйды.

Ул, Оренбур ягыннан күзен алмыйча, күңеленнән шәһәр белән бәйле истәлекләрен барлый башлады. Ә бит Оренбурдан соңгы мәртәбә китүенә әле бер ел вакыт узмады. Үткән ел күпме михнәтләр күрсәтте аңа бу шәһәр һәм шәһәр тирәсендә барган сугышлар. Дутовчылар гаять мәкерле һәм аяусыз иде шул. Ә кызылларның таркау гаскәрләре кылган гамәлләрне күздән кичерсәң, чәчләр үрә торыр. Теләсә каян җыелган партизан отрядлары, ни теләсәләр шуны эшләп, халыкның нәфрәтенә дучар булып, бөтенләй абруйсыз калып, хур булып беткәннәр иде бит ул чагында. Аңа Сызраньда оештырган отряды белән унсигезенче елның февраленнән җәйгә кадәр бу тирәләрдә авыр сугышлар алып барырга туры килде. Аерым партизан отрядларын берләштереп, көчле бер йодрыкка тупламакчы иде ул, тик алай җиңел генә хәл ителә торган нәрсә булып чыкмады бу эш. Һәр отряд командиры үзен Наполеон кебек хис итә, гел үзенекен генә алга сөрә. Шуның аркасында күпме тәртипсезлекләр, ярамаган гамәлләр кылынды бит.

Әле дә исеннән чыкмый, шулай, җәй башларында, аның янына томырылып бер үсмер килеп керде. Аның артыннан ашыгып атлаучы абзый да пәйда булды. Абзый малайны читкәрәк этәреп, алгарак үтте.

— Мин Гомәр Дәүләтъяров булам,— диде ул, үзе белән таныштырып. Ул мәгънәле итеп Усмановка карап алды:

янына кем килгәнен чамала инде, дигәнрәк фикер салынган иде аның сүзләренә. Абзый көттереп тормыйча, бу хакта әйтеп тә бирде.— Мондагы һәр укымышлы, зыялы белән бергәләп милләт өчен күп эшләр башкарган адәм булам. Менә бу егет,— диде тынычлана алмый урынында таптанып торучы үсмергә ым кагып,— Каргалыдан, Әхмәтсафа исемле. Миңа энекәш тиешле. Ул күңелсез хәбәр алып килгән, тиз генә аңлатып булса...

— Нинди хәбәр ул? — диде Усманов, яшенә караганда күпкә ныклырак тавыш белән.

Сүз башлаганда бу яшь кешегә бер дә ышанычы юк иде Гомәр абзыйның, инде андагы җитдилекне, тәвәккәллекне күреп алгач, эченә җылы йөгерде, йөзе балкып китте.

— Мин инде ике-өч кешегә барып бәрелдем, мәсьәләне Усманов кына хәл итә алыр, дип, синең янга җибәрделәр. Эш шунда — Каргалыда кызыллар бер төркем егетне җыеп, дезертир дигән булып, үзләренчә суд-мәхкәмә оештырып маташалар ди. Әхмәтсафа китергән хәбәр шул икән.

Абзыйның бөртекләп аңлатуын сабырсызланып көтеп торган Әхмәтсафа ашыгып өстәп куйды:

— Стенага терәп атабыз, диләр. Авылдан беркемне чыгармыйлар. Холыксыз кылананалар, атарлар да. Анда минем абыем Госман да бар. Тайфә әбинең улы Хәлфи абый, тагын...

Усманов күп сөйләшергә урын калдырмады. Отыры ачуы чыгып, сукранып алды:

— Ну шушы Хәйбрине! Бу көннәрдә ул йөри иде Сакмар аръягында. Җүнләп сугышканы юк, халыкның канына тоз салып йөрүдән башканы белми.

— Әйе, әйе, Хәйбри исемле командирлары. Бар кешене тотак иттеләр. Беркемне чыгармыйлар авылдан.

— Ә син ничек чыга алдың? — дип, кызыксынып-сынап сорады Усманов.

— Каргалы зур авыл бит, абый. Тишек-тошыкларын болай гына томалап бетермәле түгел,— диде малай, олыларча җитдилек белән.— Мине Дәүли абзый Сакмар аша чыгарып, Кушкүл чатына кадәр китереп куйды. Ат белән... Үзе кире борылды, егетләргә бер-бер бәла була күрмәсен дип, авылга чапты. Мин Гомәр абзыкаем янына йөгердем менә...

— Һм... Хәйбрине авызлыклап, арт сабагын укытып кайтмый булмас, алайса.

Ул ишек аша кемгәдер кычкырды:

— Федор, отрядыңда ничә кеше калды?

— Иртән егерме атлы, кырык пехота иде,— дип, берәү көттереп кенә җавап бирде.

— Безгә атлылар җитә. Сугышчыларыңны җый, хәзер

үк Каргалыга юл чыгабыз. Анда Хәйбри үз тәртибен урнаштырып йөри икән.

— Тагын нинди могез чыгарган инде?

— Мин аңа халык арасында аңлату эшләре алып барып, отрядка егетләр җыеп кайт, дип фәрман биргән идем. Ул ансат юлын тапкан — егетләрне җыеп ала икән дә, атам, дип, куркытып, отрядына китереп куша. Җайлы бит...

— Атар да. Сакмар буендагы бер авылда теге атылган егетләр мәхәтле шул Хәйбри эше. «Минем эш түгел», — дип, әлегә тана, шайтан. Күптән кыҗрап йөри — бер-икесенең маңгаена җәдрә утыртсаң, отрядыңа яз, абзыкаем, дип, халык безгә йөгереп кенә киләчәк, дигән сүзләрен күп тыңладык бит инде.

Боларны ишетү Усмановның үзе өчен дә күңелле түгел иде, Хәйбрине мондый эшкә чыгарып җибәрүенә үкенеп куйды.

— Әй шушы дуамал холыкларын! — Усманов ашыгып урыныннан торды, биленә тагылган кобурасын капшап алды да чыгу ягына атлады.

— Ярый, Гомәр абзый, сүз бозау имезә, без юлга кузгалдык. Ә мин сине беләм бит, кибетеңә китап алырга йөри идем...

— Әйтәм аны... Күргән дә сыман... — дип, аптырап сөйләнеп калды абзый.

Усманов, көлемсерәп, Әхмәтсафага эндәште:

— Син, егет, үзең белгән сукмактан кайта тор. Без күпер аша барабыз. Хәйбринекеләр син үткән кәҗә сукмагыннан атлылар килеп чыгуын күрсә, этем белсен, аңышып тормыйча, чүкеп тә куярлар.

Әхмәтсафаның тамырларында кан уйнап алды. Аның да Усманов отряды белән бергә гөрс итеп Каргалыга кайтып керәсе килә иде. Күрәсе иде Хәйбрине, каршысына Усманов килеп баскач, ни-нәрсә сөйләнеп азапланыр микән? Тик болай хыялланып, вакыт үткәреп торуы өчен үзен битәрләп алды: җитешсә генә ярар иде Усманов абый. Хәйбри дигән имансыз командир бер-бер хәл эшләргә өлгермәсә генә ярар иде. Иң яраткан Госман абыйсының да гомере кыл өстендә калды. Әгәр Усманов отряды килеп өлгерсә, шатлыгы эченә сыймас, ул бит гаять зур эш башкарды! Күпме егетнең гомерен саклап калды. Шушы уйлар эчендә, Гомәр абзыйсына рәхмәт әйтергә дә онытып, бүлмәдән чыгып йөгерде.

Усмановның кечкенә отряды килеп кергәндә, авылда мәхшәр купкан иде. Яңа мәчет диварына Хәйбри гаскәриләре унлап егетне тезеп куйганнар. Хәзер алар зур эш башкаргандай халык алдында кәперәеп йөргән Хәйбридән соңгы боерык, фәрман көтәләр иде.

Авыл урамнарын дер селкетеп, кинәт чабышып килеп кергән атлылардан Хәйбри бер каушап калса, килә-килешкә ат өстеннән җиргә сикереп төшеп, җилләнеп каршысына килеп баскан комиссар Усмановны күреп, яңа гына әтәчләнеп йөргән командир кисәге бөтенләй мәлҗерәп төште.

— Тагын ни майтарасың, Хәйбри? — диде Усманов, үтә канәгатьсез тавыш белән.

— Ни бит, иптәш Усманов... Бераз агарту эшләре алып бармыйча булмый, кызыллар отрядына язылам дип торучы юк. Шуңа, мин әйтәм...

— Аңлашылды, халыкны агартмыйсың син, канга батырып йөрисең! Күрәсеңме, халык сиңа нинди нәфрәт күзләре белән карап тора. Үзеңнең борыныңнан ары бернәрсәне дә күрмисең, ахры, син. Корал бит ул, егеткәем, акыллы кулга эләксә генә илгә, халыкка файдага эшли. Синең ише дуамал җанга корал биреп ялгышканбыз без.

— Миңа ни... Фәрман үтәп йөреш. Йә кайсыгыз минем кадәр гаскәр җыйды отрядка?

— Бүген бауга тагып алып кайтасың, ике-өч атнадан коралларын ташлап, качып, таралышып бетәләр. Шул булдымы эш?

— Бәтәч, иптәш комиссар, ансын инде сез үзегез карагыз. Тәрбияләгез, агартыгыз, качырмагыз. Шул да булдымы революцион тәртип?!

— Бөтен хикмәт тә шунда инде, Хәйбри. Революцион тәртип дисең икән, ул синең үзеңнән башланырга тиеш. Кара инде киемеңә — башыңда казак папахасы, аягыңда үзбәк читеге, өстеңдәге гимнастеркаң каешланып каткан. Үзең командир саналасың.

— Көлмә инде, иптәш Усманов. Монда үзеңне карарга вакыт бар ди.

Усманов ачуын яшерми сөйләвен дәвам итте:

— Солдатларыңны күр — революция солдатлармы алар, әллә юлбасарлармы? Аерып алмалы түгел. Хәзер үк отрядыңны җый, үзләрен тәртипкә китерсеннәр, ә мин халык белән сөйләшеп алам, — дип, Усманов, яңа мәчет янына тезелеп баскан, башларын аска иеп, сүзнең ни белән бетәсен тын да алмый көтеп торган егетләргә таба борылып, күтәренке тавыш белән:

— Нәрсә бөрешеп басып торасыз? — дип кычкырды. — Барыгыз, өйләрегезгә йөгерегез, әти-әниләрегез хафаланмасын. Кызыл гаскәрләргә көчләп алып китү булмаячак!

Шушы сүзне ишетүгә, егетләр дәррәү урыннарыннан кузгалып, күз ачып йомганчы, җыелган халык арасына кереп югалдылар. Сафта ике егет кенә басып калды.

— Сез ни көтәсез?

Егетләрнең берсе алгарак чыгып, каушый төшеп сүз башлады:

— Рәхмәт, иптәш командир... Хәйбри-җанкыярны акылга утыртуыгыз өчен мең рәхмәт... Мин Тайфә карчык малае, Хәлфетдин. Безне атарга алып чыгалар, дигәч, инәй-карчык йөрәге тотып егылды. Өйгә кайтып, аны юатып киләсе булыр. Өйләргә таралганчы сезгә сүзебез бар иде.

— Тыңлыйм.

— Без менә Мочтай... әй лә, Мостафа абзый малае Госман белән уйлаштык та сезнең отрядка языласы иттек.

Усманов өчен Тайфә карчык кем дә, Мостафа агай кем — ул кадәресе әһәмиятле түгел, ә егетләрнең үз теләкләре белән отрядка кушылырга теләүләре бик мөһим иде. Дулкынланудан аның йөзенә алсулык йөгерде. Ул бер читтә ризасыз кыяфәттә басып торган Хәйбригә ачулы караш ташлады.

— Дөрес уйлыйсыз, егетләр. Вазгыять шундый, чормада ятып та, печән кибәне астына яшеренеп тә Рәсәйдә барган хәлләрдән качып котылып булмый.— Аның сүзләрен шым гына тыңлап торган Госманның йөзенә кызыллык йөгерде, ул нәрсәдәндер оялган сыман башын түбән иде. Усмановның күзеннән шаян чаткылар сибелде.— Нәрсә, егет, кыек атып туры тигездемме әллә?

— Өстенә бастыгыз дисәң дә була, иптәш комиссар, ул егетне чормадан өстерәп төшердек,— дип сүзгә кысылды Хәйбри.

Усмановның йөзе җитдиләнде.

— Синең кыланмышыңнан җәһәннәмгә качардай булырсың, Хәйбри...

Моңарчы дәшми торган Госман телгә килде.

— Кемгә ышанырга белмәссең, кем килсә, шул үз гаскәренә куа. Бертуган абыем Гомәрхан әнә Муса Мортазинның полкына язылган иде. Кызыл гаскәргә дип, озак та үтмәде, Мортазин башкортлар ягына чыккан, диделәр. Шулай булгач, кемгә ышанырга соң?

— Әйе, андый ялгышлык булды. Ул көннәрдә аңлашу җитмәде. Хәзер Мортазин да, башкортларның башка частьлары да кызыллар белән күмәкләшүгә каршы түгел. Безгә һич тә аерымланырга ярамый. Шушы чорда татар-башкорт мөселманнары файдасына нәрсә дә булса эшләп өлгерә алмасак, соңыннан үкенергә туры киләчәк. Сугыштан соң батырлар күбәя. Тыныч тормышка күчеп, милләт ягын кайгырта башласак, Мәскәүдәге башлы агайлар: «Без фронтларда кан койганда, сез, мөселманнар, үзара талашып, ызгышып яттыгыз, хәзер ни-нәрсә таләп итмәкче буласыз», — дип көләчәкләр генә. Шуңа күрә революциядә җиң сызганып

катнашырга кирәк дип саныйм. Безнең язмышны үзебездән башка беркем дә хәл итәргә тиеш түгел. Минем большевиклар сафына басуым, кызыл гаскәр туплап, ак казакларга каршы сугышуым нәкъ шуның өчен дә. Моны мин генә түгел, сез дә шулай аңласагыз иде. Ул чагында Хәйбриләрдән качып чормада ятасы урынга, революцион гаскәрләрнең иң алгы сафына килеп кушылырсыз. Шуларны аңлаган хәлдә минем отрядка кушылырга ниятлисез икән, рәхим итегез, бер каршылыгым да юк.

— Рәхмәт, рәхмәт, — диештеләр егетләр, комиссарның үзләре белән шулай дустанә сөйләшүенә сөенеп.

— Рәхмәтне миңа гына түгел, штабка нәкъ вакытында килеп җиткән җегеткә дә әйтергә онытмагыз, — диде ул, елмая төшеп.

Усмановның сүзен ишетеп, тарала башлаган халык тукталып, тагын җанланып алды.

— Кем, кайсы җегет турында сүз бара? — диде бер агай.

Мактана төшеп, тамак төбе белән икенче абзый сүзгә кушылды:

— Минем малай, Әхмәтсафа... Дәүли Кушкүлгә кадәр ат өстендә озатып куйды. Тәки барып җиткән, эзләп тапкан бит, шайтан алгыры. Әнә үзе дә әйләнеп кайтып килә, — дип, үтә дә җитди кыяфәттә ашкынулы адымнар белән мәчеткә табан килүче үсмергә күрсәтте.

— Мочтай малае икән... — диде бая сорау биргән агай, канәгать тавыш белән. — Үткер күренә, Каешныкылар икәне атлавыннан ук сизелеп тора.

Әхмәтсафа, җыелган халыкның, команда буенча дип әйтерлек, дәррәү үзенә табан борылып каравына кыенсына төшеп, әтисе янына килеп басты. Мостафа улын башкалардан аралап алырга теләгәндәй, нык итеп җилкәсеннән кочаклап, һәркем ишетерлек итеп мактап алды:

— Маладич, улым! Госман абыеңны йолып калдың бит тәки.

— Хәлфетдин абый кая соң? — дип, беркатланып сорап куйды Әхмәтсафа.

— Барысы да исән-имин. Өйгә йөгерделәр әнә.

Мәчет янына җыелган халык шушы шөбһәле һәм чарасыз үткән берничә сәгать эчендә тәмамсы арып-алҗып беткән иде, тоткын егетләр азат ителгәч, бу тирәдә чуалуның кирәге калмады, бәладән башаяк дигәндәй тарала башлады.

Усманов шактый талчыккан Әхмәтсафага кулын сузды:

— Булдырдың, егет икәнсең! — Халыкның алны-артны карамый таралуын күреп, мәчет баскычына сикереп менде һәм кулын өскә күтәрде:

— Җәмәгать, таралмагыз әле!

Авыл агайлары, «бусы нәрсә инде тагын?» дигәндәй сәерсенеп, теләр-теләмәс кенә кире борылдылар, сагайган карашларын яшермичә, Усманов тирәсенә елышып, ярымтүгәрәк ясап бастылар.

— Җәмәгать, бер җитешеп килгәч, гәпләшеп тә алыйк инде,— диде ул, уенын-чынын кушып.

— Телгә оста, нәләт төшкере,— диде арадан берсе.

Усманов дәвам итте:

— Шушы гүәрдин сыман егетләргә карап тордым да уйлап куйдым. Ярый, без китәбез, иртәгә, әйтик, ак казаклар килеп керер, егетләр алардан да котылып калыр, тагын икеөч көннән башкорт җайдаклары кереп тулыр авылыгызга. Һәркайсы үзенчә мобилизация, ягъни солдат җыйнау турында карар игълан иткән. Без дә Ленин фәрманы буенча гаскәр җыябыз. Татарларны инде апрель аеннан бирле Кызыл Армиягә язу бара. Шундый хәлләр... Ничек саклап калырсыз соң алга табан егетләрегезне? Ә бит мобилизациядән сәбәпсез читләшкән кеше дезертир булып санала, ә сугыш чорында дезертирны, үзегез беләсез...

— Менәтерәк шунсын аңлап бетереп булмый да инде, иптәш-әфәнде командир. Әллә аңлата белүче юк, әллә үзебезнең баш юка,— дип, сөйләнә-сөйләнә алгарак чыкты бер агай. Ул, тел төбендә хикмәтле фикер ятканны искәртергә теләгәндәй, сакал-мыегын учы белән нык кына сыйпаштыргандай итте.— Килүчеләр күп анысы, һәркайсы мөселман исеменнән сүз йөртә. Без инде, яшерен-батырын түгел, татар, башкорт дип өйрәнмәгән. Мин үземне кем дип тә белмим, татармы, башкортмы, фаразан?.. Тфү-тфү, әйтмәгәнем булсын, күзем чәчрәп чыкса да, денем белән, иман-вөҗданым белән теләсә кайда үземне мөселман дип раслый алам.

— Без дә мөселман бригадасы,— дип, аны җөпләде Усманов һәм ялгап алып китте.— Катлаулы мәсьәлә бу. Нәкъ шуның аркасында Вәлидовчылар белән аерымлану килеп чыкты.

— Анысы кем тагын? — дип сорады арадан берәү.

— Башкортларның патшасы,— дип җавап кайтарды аңа Мостафа, белдекле рәвештә.

— Ишкәннәр икән...

Сорау бирүченең әлеге сүзләреннән көлешеп алдылар.

Усманов кызуланып:

— Әйе,— диде,— барыбыз да мөселманнар. Шунысын гына онытмаска киңәш итәм: мөселман дөньясы катлаулы, хәтта каршылыклы да. Барлык диндәшләребез өчен җавап тотасы килми, әмма Идел-Җаек арасындагы төбәкләрдә яшәүче татар, башкорт халыкларына берләшергә кирәк. Безне

Солтангалиев кебек юлбашчыларыбыз шуңа өнди. Үзегез күреп торасыз, көчкә көч белән генә каршы торып була. Кем рәхәт күрсәтте сезгә? Патшамы? Ак казакларммы? Әллә Вәлидов рәхәт тормышка чыгарыр дип уйлыйсызмы? Алай булмый ул, җәмәгать. Берләшүдән гайре башка чарабыз юк. Без, әгәр милләт булып яшисебез килә икән, шушы юнәлештә кичекмәстән хәлиткеч адымны ясарга тиешбез. Киләчәккә карап эш итәргә өйрәник, җәмәгать...

— Быелның ярингәсе, таңдагының ахирәте бар,— диде арадан берсе.— Булырның бавы озын шул аның, туганкай. Тормышның көе китте, тозы чамалы нотыклар тыңлап яшәүләре ялыктырды инде.

— Дөрес. Дутов та Идел-Җаек арасында учредилка мәмләкәте дип, сезнең башыгызны бутап йөри әнә. Башка коткы салучылар аз түгелдер. Аңа кушылган Вәлидов халыкны, юк-бар нәрсәләргә ышандырып, Дутов белән берләшергә чакыра, җитмәсә.

Моңарчы Усмановны тыныч кына тыңлап торган калын кашлы адәм дөрт итеп кабынды:

— Алар берләштеләр, сез дә кушылыгыз! Вәссәлам бит инде шуның белән. Үзем түрдә, сүзем үрдә дип кенә сүләнәсең, агай-эне. Берләшәсе килгәнгә беркем дә комачау ясамый. Ник сузасыз?

— Дәүли дөрес сукалый. Ун дәрвиш бер келәткә сыя, ике патша бер икълим-кыйтгага сыймас, дигән борынгылар. Патшалар күбәйгән саен, җир тарая.

Усмановның бирешергә исәбе юк иде.

— Алар ни өчен берләштеләр соң? Төп идея — Татар-Башкорт республикасы төзүгә каршы берләштеләр бит алар, ягъни берләшүгә каршы берләшү булып чыга. Ләкин Дутовка, әгәр аның уй-нияте тормышка ашса, Вәлидов кирәкме, башкорт мәмләкәте кирәкме? Юк, кирәк түгел. Урыс монархиясенә, ягъни урыс патшасына  ант эчкән Дутов мөселман өчен бармагын да селкетмәячәк. Ә көрәшкә өндиләр. «Көрәш» сүзе матур сүз, тик ни өчен көрәшкәнне белергә кирәк. Әнә Сакмарга карагыз, ничек дәртләнеп, ашкынып ага ул! Мин үзем Оренбурда туып, шунда үскән, укып белем җыйган кеше. Яз көне бозлар актарылганда бигрәк матур, ямьле була иде Сакмар. Тик ярдан карап торганда гына матур. Шул актарылган елгага кереп карагыз әле. Исән калырсызмы? Сезнең башны әйләндереп йөрүчеләр дә шулай, матур сөйлиләр, ә эчтәлеге бер —  шул сүзләргә ышанып ташкынга кереп китсәгез, берегез дә исән чыга алмаячаксыз.

— Сине уздырганы юк иде сыман... Бигрәк шома сиптерәсең. Ат сөртенми җир танымас, ир сөртенми ил танымас,

әйтүе генә җиңел, дөреслекне бер Ходай белә,— диде Дәүли, бер дә Усманов белән килешәсе килмичә.

— Мактавыгыз өчен рәхмәт. Телгә анысы кесәгә керешле түгел,— диде Усманов, ак тешләрен күрсәтеп елмаеп.— Яшермим, максатым — мөселман гаскәрләрен җыеп бер йодрыкка туплау. Яулар кичкән кеше буларак әйтәм, бердәм һәм кулында коралы булган халык белән генә хисаплашалар. Кулга корал алгансың икән, ни өчен яуга керүеңне бел. Сәгать сукты, мөселман халкына азатлык яулап алырбыз, бабайлар моңарчы гасырлар буе хыялланган ирекле дәүләтебезне торгызырбыз. Оренбурда төзелгән мөселман батальоны комиссары буларак әйтәм — көч безнең якта, халык безнең якта. Без — җиңәчәкбез!

...Кисәк әче итеп паровоз сызгыртып куйды. Усманов хатирәләреннән айнып китте. Мәзәк хәлдә калганын да шәйләп алды — үзе дә сизмәстән, йодрыгын күккә чөеп җибәргән хәлдә тора икән бит! Ул артка борылып карады, күреп калучы булмаганмы, янәсе. Күзгә кеше-фәлән чалынмагач, тынычлангандай булып, кырт борылып, штаб урнашкан вагонга керергә кузгалды. Оренбур якын, инде бик якын иде...

## III

Унсигезенче елның борчулы көннәре хәтердән чыгарлык кына түгел шул...

Ул көнне Әхмәтсафа өлкәннәрнең сөйләшүен тыңлап бетермәде, өйләренә ашыкты. Шулай да Дәүли абзыйның акыллы һәм көчле Усмановка каршы төшеп маташуын өнәп бетермәде. Көчле булмас ди сиңа! Хәйбри аны күргәч, шәлперәеп, шәрә бүре хәлендә калды. Каргалы никрутларын (әткәсе сүзе) котылгысыз һәлакәттән йолып кала алуына малайның түбәсе күккә тигән иде. Баш өстендә өерелеп йөргән болытлар да, Җаек буеннан кисәк-кисәк исеп куйган салкынча җил дә аның бу күңел күтәренкелеген баса алмады. «Өлгердем бит! Госман абыйны коткарып калдым, шөкер» дигән уй аны күкнең җиденче катында йөртә иде. Ул хәзер атлап барган, озакка сузылган яңгырлардан тәмам җәфаланып, изерәп беткән сукмак та әйтерсең Оренбурның таш түшәлгән юлларыннан ким түгел. Малай, арыганын онытып, киртә буйлап сузылган сукмактан йөгерә-атлый, йөзе кояштай якты, бүселеп торган көнгә дә исе китми — бүген бәйрәм, чын бәйрәм иде аның өчен.

Шул уйлар белән барганда, Ишан мәчете тыкрыгыннан капыл каршысына Вәлкәй хаҗи килеп чыкты. Уңны-сулны искәрми кайткан малай барган шәпкә хаҗига бәрелә язып,

соңгы чиктә сукмактан читкә каерды. Үзе исә әллә шүрләп, әллә уйларыннан айнып бетә алмый:

— Һәй-лүк!..— дип, сөрән салганын сизми дә калды. Әйтерсең киң дала буйлап сарык көтүе куып бара.

Үсмердән мондый кыланмышны, бернинди аратага сыешсыз пырдымсызлыкны көтмәгән Вәлкәй хаҗи шыр җибәрде бугай, кулындагы кәкре саплы таягын сөңге сыман күтәреп, Әхмәтсафаның күкрәгенә китереп төртте.

— Мәлгунь, күзеңә бәрәңге үскән нәләт, артыңны кыргычлап, борыч белән уасы нәмә, ни уйлап шакмак күзеңне киереп ачкан көйгә мәчет әһелияте өстенә килеп менәсең, ә?! — дип чинап җибәрде ул. Әллә тагын Әхмәтсафа аны почмакта юри саклап торып, шулай куркытырга уйлаган.

Малай чынлыкта шүрли төшкән иде, шундук теленә килгән беренче сүзләрне әйтергә өлгерде:

— Хәерле көннәр булсын, азанчы бабай!..

Бу сүзләргә Вәлкәйнең ачуы отыры көчәеп кенә китте.

— Мөселманча, китапча сәлам дә бирә белмисең, йолкыш. Мифтах хәлфә бозган нәмәкәйсеңдер инде. Әссәламегаләйкүм, хаҗи хәзрәтләре, диген, атың коргыры.

Азанчы дөрес әйтә иде. Каргалы тирә-якта гына түгел, бөтен татар-мөселман илендә барыннан да бигрәк үзенең мәчет-мәдрәсәләре, диндарлыгы белән дан тоткан авыл. Чулман, Җаек буйларында яшәүче укымышлы һәр мөселман изге сәфәр — хаҗга барырга уйласа, сәфәрнең нәкъ менә Каргалы аша үтүен хуп күрер иде. Озын һәм билгесез юлга чыгар алдыннан, ике-өч ай мондагы абызагай — гыйлем ияләре хәзрәтләрдән, хаҗ сәфәрендә булып кайткан тәкъва картлардан бу изге эшнең низам-кануннары хакында озаклап һәм тәфсилле аңлатмалар алалар. Хаҗ турындагы белемнәрен арттырып, кирәгенчә төшенгәннән соң гына Каргалыдан кубып китәләр иде. Тик, ни гаҗәп, дини йолаларга, гореф-гадәтләрнең какшамас кануннарыннан бер мыскал читкә авышмаган Каргалыда да берзаман, иске тәртипләрнең үтәлешен ныклы күзәтүдә торкан абызагайлар уенча, җәдитчелек дигән нәмәхрәм мәктепчелек үтеп керде. Иң беренче Гомәр Дәүләтъяров кебекләр сәбәпче булды моңа. Ул, яшьтән үк үз көнен үзе күрә башлаган зиһенле сәүдәгәр, Оренбурга күчеп, бер дә ярашмаган эшкә тотынды. Иң беренчесе, шөкәтсез озын чәчле, җилбәзәк кыяфәтле, әмма үз якларына үтә дә зирәк сукалаучы мөгаллимнәр, нәширләр белән дуслашып алды. Авылга чат ябышып яткан яшьләрне шәһәрдәге мәдрәсәләргә гыйлем җыярга барырга күндерде. Ул гына җитмәде, Каргалыда — хак мөселманнар «икенче Мәккә» дип атап йөрткән шанлы салада — җәдитчә мәдрәсә ачтыруга ирештеләр. Гомәр Дәүләтъяровны, аның тарафдарла-

рын кадими имамнар егълый-егълый каргасалар, җәдитчеләрне яклаучылар да аз түгел иде. Озак та үтмәде, бөтен мөселман дөньясын үзләренең диндарлыклары белән шаккатырган Каргалы шәкертләренең аңнарын саташтырырга әллә кайдан Мифтах атлы хәлфәне табып китерделәр. Анысы бигрәк тә үҗәт булып чыкты: мең дә бер каршылыкны җиңеп, янау-куркытуларга, туктаусыз һөҗүмнәргә карамый җәдитчә укытуны оештырып җибәрде. Шулай итеп, егерменче гасыр башында, Каргалы имамнарының гасырлар буе бөртекләп җыйган абруе сизрәп төшкән мендәр сүрүе кебек сыпыла башлады. Шәкертләрен әйт, күрәсең, халыкта дини белемнәр белән рәттән дөньяви белемнәргә дә омтылыш шулкадәр көчле булгандыр — хәзрәтләренең бәддогаларына, янау-куркытуларына керфекләрен дә селкетмәгән кыяфәт белән, һич икеләнмичә, Мифтах хәлфә ягына авыша башладылар. Җитмәсә, авылда кызлар мәктәбе ачылды. Монысына нәсел-тумышлары белән Каргалы кешеләре саналган Хөсәенов байлар тырышты. Аларга ярдәмгә алтынчы Закир Рәмиев килеп кушылды. Гомергә күрелмәгән хәл, әлеге мәктәпкә Оренбур, Троицк кебек шәһәрләрдән үсмер кызлар җыелды. Сусаса да сусар икән халык белемгә!

Авыл картлары, кадими мулла-имамнар да бирешергә теләмәделәр. Тырышлык куеп йөрүләре бушка китмәде тагын, кызлар мәктәбен яптырганнар иде яптыруын. Тик дөньялар буталып китте, Оренбур байлары янә ачтылар мәктәпне. Менә шулай кадимчеләр белән тарткалаша-өзешә түнтәрелеш дәверенә килеп керделәр Каргалы җәдитчеләре.

Әмма кадимчеләр Дәүләтъярныкыларны җай килгән саен каһәрләүләрдән, сәбәпле дә, сәбәпсез дә битәрләүдән туктамадылар. Әйтерсең Каргалыга үтеп кергән җәдитчелеккә генә түгел, ә дөньяның астын өскә китергән түнтәрелешнең дә төп гаепчеләре шушы тынгысыз нәсел кешеләре иде. Һәр эшнең башында алар йөргән кебек, нәкъ менә алар таяк белән болгата кырмыска оясын. Вәлкәй хаҗиның котыруы да тикмәгә түгел, кинәт каршысында пәйда булган әлеге үсмер дә Мочтай малаена охшаган, туп-туры күзгә карап торулары, гөнаһсыз көлемсерәве гел әтисенеке икән. Теле телгә йокмый әҗәткананың:

— Әйе, Вәлиулла бабай, Мифтах хәлфә шәкерте мин,— дип чатнатып ярып салды, тоз күз. Үзләренә шайтан гыйлеме өйрәтеп яткан хәлфәсе белән горурланган да төсле. Их, дөньясы бозылды, ачуым бер килмәгәе, дип уйлап, эчтән сызып куйды Вәлкәй хаҗи. Элгәре чорлар булса...

— Нинди бабай булыйм мин? — дип, рәнҗеп кычкырды ул ярсулы тавыш белән үсмергә.— Бар, бар, юлыңда бул, малай актыгы! Шул Мифтах хәлфә бозып бетерде сезне.

Шаккатырсың, ник кирәк авыл баласына җәгърәфия, хисабы ник кирәк, акча булса, анысын гына саный беләсең аны. Урысча укытуны сөйләп тә торасы юк, диннән яздыруга тиң гамәл, гөнаһ шомлыклары...— дип тезеп китте ул, үсмернең корт чагудан качкан кебек өйләре ягына элдертүенә игътибар итмәстән.— Дөньясын урыс акылы бутады инде. Ерак китәрсең менә урыс акылы белән. Кайчаннан бирле болганалар, әле илнең тынычланырга исәбе юк...

Өйләре турына җитәрәк Әхмәтсафаның каршысына берберсе белән узыша-узыша ике бала йөгереп чыкты. Болар — энесе Әхмәтхан белән сөйкемле сеңлесе Бибиҗамал иде. Иркә кыз килә-килешкә абыйсының тезләренә сарылды:

— Олы абый китәм әйтә,— диде ул, сабыйларча тәтелдәп.— Миңа мәми алып кайтам, дип әйтә.

— Кая китә Госман абый? — дип аңыша алмый Әхмәтханга карап сорау бирде ул.

— Сугышка китәргә җыена...— диде Әхмәтхан, борынын мышкылдатып.— Хәлфетдин абый да кызылларга язылган.Ул да китә...

Абыйсына сөйләп бетерергә ирек бирми, Бибиҗамал күргән-ишеткәннәрен җилгәрә башлады:

— Әйе, абыкай, Хәлфи абый да китәм әйтә. Инәй елый, китмә әйтә.

Әхмәтсафа аптырап тагын Әхмәтханга карады. Энесе һушлы бала, көттермәде:

— Тайфә әбиләргә барганыек. Барып керсәк, инәй Хәлфи абыйны кочаклап: «Ике аягыңның берсен дә атламыйсың, син киткәч, мин нишлим?» — дип үкереп елый. Хәлфи абый әйбәт бит ул, өйдәге бөтен эшне ялт иттереп кенә тора. Шуңа инәйнең җибәрәсе килми аны, иеме? Госман абыйга бер сүз дә әйтмәде. «Үзең беләсең инде»,— дип кенә куйды әнә. Тайфә әби өйдә юк, югары очтан кызлары килеп алып киткәндер инде.

Энесенең бу хакта сүз озайтуын теләми иде Әхмәтсафа. Җитмәсә, тел бистәсе сеңлесе янында. Үги инәйнең юкка гына Хәлфине калдырырга теләмәгәнен сизенә иде ул. Тик Госман абыйсының армиягә язылып китәргә җыенганы турында әткәсе бер сүз дә әйтмәде. Әллә Госман абыйсы өйгә кайткач кына шундый карарга килгәнме? Әткәсе, бер хәбәрсез, комиссар Усмановка мөкиббән китеп, һаман ул сөйләгәннәрне тыңлап тора микән мәчет янында?..

Ул сеңлесен күтәреп алды да Әхмәтханга дәште:

— Хәзер үк әткәйне алып кайт. Ул Яңа мәчет янында булырга тиеш.— Аннан шыпырт кына: — Инәй белән Хәлфи абый турында сөйләнмә, ярыймы,— дип тә өстәде.

Әхмәтсафа сеңлесен күтәргән килеш ишегалдына үтте. Каргалыда ишегаллары бик үк киң түгел. Мостафа агайның ишегалды, башкалардан аермалы буларак, шактый иркен. Ихатада саман кирпечтән салынган кара-каршы ике өй. Берсе — гадәттә балалар йоклый торганы — кече өй, икенчесе — акбур белән агартылганы, олы өй дип йөртәләр. Аларны салкын тынлык каршы алды.

Госман кече өйдә, мич буендагы бүкәндә, нindидер гаеп эшләгән кеше сыман башын түбән иеп, үз уйларына йотылып утыра иде. Энесе белән сеңлесе кайтып керүгә куанды, ахры, йөзе бераз яктыра төште.

— Әткәй кайтмадымы? — дип сорады ул, сүлпән генә.

— Әхмәтхан алып кайта хәзер... Сине коткарам дип чапкан булам мин, ә син... — дип, үпкәләгән тавыш белән Әхмәтсафа сүз башлаган иде, Госман әкрен генә урыныннан күтәрелеп, энесе янына килде һәм аның кулыннан Бибиҗамалны алып күкрәгенә кысты.

— Шулай кирәк, энекәш...

— Хәлфи абый да китәргә җыена икән.

Госман хәсрәтле көлемсерәде.

— Китәр, китми кая барсын...

— Инәй китмәскә үгетли икән дә...

Нигәдер риза булмыйча, Госман чыраен сытты.

— Бу ут борчалары барып та кайтканнар икән,— дип, ул сеңлесен сак кына идәнгә төшерде. Бибиҗамал шуны гына көткән кебек ишектән чыгып тайды, аңа ни, уйнарга гына булсын. Госман, әһәмиятле хәбәр әйткәндәй, кулын энесенең җилкәсенә салды.— Бөтен хикмәт тә шул Хәлфетдиндә, энекәш. Бүген мин аның белән нык кына сөйләштем. Йә икебез дә армиягә язылабыз, йә мин сине бәреп үтерәм, дидем. Тик син моны беркемгә сөйләмә. Үзең бел дә май кап. Килештекме?!

Әхмәтсафа берни аңламый, иңсәсен җыерып куйды.

— Нигә алай әшәке әйттең Хәлфи абыйга?! — диде ул, Госманның дуамал сөйләшүен өнәмичә.— Хәлфетдин абый булмаса... Сез бит гел читтә йөрисез. Әткәй дә кайтып керми. Дөньяны инәй белән алар алып бардылар.

— Юк сүз бозау имезә. Менә сугышлардан исән-имин әйләнеп кайтыйк, син дә исәя төш, бер иркенләп сөйләшеп утырырбыз икәү генә. Хәзергә мин әйткәнне тыңла. Бу хакта беркемгә дә тишмә. Сер булып калсын.

Җилләнеп әткәсе кайтып керүен күреп, икесе дә тын калдылар.

— Ни уйлап чыгардың син, бала? — диде Мостафа агай, өйгә кергән уңайга. Тиз кайтудан аның сулышы киселә, көчхәл белән генә тын ала, аһылдап сәкегә килеп утырды.

Госман аптыраулы кыяфәттә әткәсенә күтәрелеп карады.

— Болай булмый бит инде, — диде ул, йөзендәге кызыллыгын куарга теләгәндәй кулы белән йөзен сыпырып. — Үзең уйла, әткәй, өй чормасында күпме качып ятарга була? Оренбурда яшәү тагын да куркынычка әйләнде, өйдә ятышлы түгел — балалы өйдә бур тормас, ди. Барыбер табып алачаклар. Кайсы як килсә дә, күзләренә чалынасың икән, дезертир, дип атып кына үтерәчәкләр. Ичмаса, үз теләгең белән бер якка кушылсаң... Инде егерме яшь миңа, аңла, әткәй...

Мостафа агай тирән уйда дәшми торгач, әкрен генә:

— Инәгез кайда? — дип сорады.

— Тайфә карчыкларда... — диде теләмичә генә Госман.

— Бар, улым, Әхмәтсафа, алып кайт әле инәңне...

...Тайфә карчык өенең болдыр баскычына аяк басуга, Әхмәтсафаның колагына үги әнисенең еламсыраган тавышы ишетелде:

— Юк, Хәлфетдинкәем, уйлама да! Син китеп мин нишлим? Телисең икән, әйдә икәүләп җәһәннәм аръягына олагабыз. Ялгызымны гына калдырма, — дип өзгәләнә иде Шәмсия әнисе.

Хәлфетдин нидер быдырдый, аның сүзләре аңлашылмады. Үги әни аны тыңлап та тормады, сулкылдап елап җибәрде:

— Ә мин... Нигә үзең турында гына уйлыйсың?..

Өйгә генә сыймыйча, тышка ук ишетелеп торган бу тартышның серен хәзер бөтен тирәнлеге белән чамалый иде инде Әхмәтсафа. Йортка үги әни килеп ике еллап чамасы үткәч, әтисе үзләренә хезмәтче егет алды. Ул — Тайфә карчыкның бик тә сүз тыңлаучан, акыллы һәм чибәр улы Хәлфетдин иде. Аны балалар да яратты, тора-бара шуны сизенде Әхмәтсафа — егетне үги әнисе дә үз итте, ахры.

Әтиләре кыш буе юньләп өйдә тормый, дала ягына тиреяры җыярга чыгып китә, өйдәге бөтен эш элек Гомәрханга өелеп кала иде. Соңгы елларда сәфәр йөрү куркыныч була башлады дип, аннан соң эшкә өйрәнә торсын дигән уй белән дә әтисе Гомәрханны да үзе белән юлга алып чыга башлады. Госман исә Оренбурда, Гомәр абзый кибетендә пыр тузып сәүдә эшенә өйрәнә. Кыскасы, өйдәге мал-туарны карау бер Шәмсиягә генә калганлыктан, Хәлфетдиннең хезмәтче булып килүенә иң нык сөенүче дә, әлбәттә, үги әнкәсе иде. Хәлфетдин дә тиз ияләште. Кайбер чакларда, әгәр малайлар тыңламый башласалар, үги әни аларны Хәлфетдингә әйтү белән генә куркытып тыя иде:

— Карагыз аны, малайлар, тагын сугышсагыз, белегез, Хәлфетдин абыегызга әйтеп, колагыгызны бордырам! Болай булса, әткәгез кайтканчы, өйне ишеп төшерәсез сез. — Үзе астан гы-

на яратып Хәлфетдингә карап ала.— Әле әткәгез кайчан кайта...— Шәмсия әнинең тавышында әллә өмет, әллә өметсезлек чагылып китә. Хәлфетдин сәер генә тамак кырып куя.— Кайтып керсә дә өйдә тора алмый ул...— Бу сүзләрне ул Хәлфетдинне юатырга теләгәндәй әйтә.— Артын сәкегә терәргә өлгерми, Дәүли агай килеп җитә, тагын казакълар арасына барып, сөйләшеп кайткан, тире төяп җибәрергә көтеп кенә торалар, ди. «Дәүлинең сүләшүен әйтерием,— ди Мостафа,— барсаң, ай буе тире җыелганын көтеп ятарга туры килә»,— дип сукрана-сукрана тагын чыгып китә.

— Байларга ни, кеше генә булсын куалап йөрергә. Беләләр бит Мостафа абзый китә икән, буш кул белән кайтмый,— дип сүзгә нокта куймакчы була Хәлфи.

— Өйдәгеләрнең нишләве, ничек көн итүе ике ятып бер төшенә керә микән, юкмы?! Ярый инде, акылына килеп, сине хезмәтче итеп алды...— Соңгы сүзне әйткәндә аның йөзе тулышып, алсуланып, үги инәй тагын да чибәрләнеп китә. Мондый сөйләшүләр башта Әхмәтсафа алдында булгаласа да, соңрак алар икесе генә, ниндидер үтә яшерен серләре бар кебек чыш-пышка күчә башладылар, яннарында Әхмәтсафа пәйда булса, сүзләре шундук өзелә, Хәлфетдин исә, май ашаган мәче шикелле, мыштым гына бу тирәдән сызу ягын карый иде.

Дөньялар болганып, яшьләрне көчләп армиягә ала башладылар. Үткән ел гаскәргә алынудан качып йөргән берничә егетне Сакмар буена чыгарып атып та киттеләр кызыллар. Бүген комиссар Хәйбри, күзен дә йоммый, янә дә дезертирлар табыла икән, судсыз-нисез атабыз, дип куркытты халыкны. Госман шактый вакыт чормада качып ятты. Тик бөтен җиргә җитә торган Әхмәтхан аның кайдалыгын белеп алып, «сер» итеп кенә өч яшьлек Бибиҗамалга әйтеп өлгергән.

Берзаман Бибиҗамал дөнья яңгыратып үкерә башлады:

— Олабкай янына менгерегез! Олабкайга барам!— «Олабкай» дигәне — «олы абзыкай», ягъни Госман була инде.

Нихәл итәсең, кызый җиңде, абыйлары ярдәмендә чормага үрмәләп менә башлады. Госман сеңлесе өчен җанын ярып бирергә әзер, моны сабый күңеле тиз сизеп алды, аның яныннан төшми дә башлады диярлек. Ул гына да түгел, берәр нәрсәгә ачуы килсә, бу түгәрәк йөзле, сары чәчле курчак кебек кызчык, абыйсын шаштырыр дәрәҗәгә җиткереп, чорманы тутырып дулый башлый иде:

— Әйтәм, әйтәм!.. Качып ятасың, урамдагы мылтыклы абыйларга әйтәм. Мине яратмасаң, кычкырам!

Госман ахыр чиктә түзә алмады, чормадан төшеп, танышбелешләрдә кунып йөрде. Тик бу эш тагын да хәвефлерәк: үз өендә дезертир качырып яткыруны беркем дә өнәп тор-

мый. Әгәр көннәрнең берендә, кемнәрдер килеп, өйләрендә яшеренеп ятучы су сөлеге кебек егетне тапсалар, йорт хуҗасына ни-нәрсә буласын кем белә... Сакланганны саклармын дигән бит Ходай. Госманның хәле болай да мөшкелләнеп бара иде. Бүген исә Сакмар буенда язгы ташу ярга чыгарып аткан бүрәнәләрне җыеп мәшәләнгәндә, аны кызыллар килеп эләктерде. Ни булса шул булыр, исән калырга язса, үзем теләп китәм кызыллар ягына дип, ныклы карарга килгән иде. Әмма үзе генә түгел. Ул чормада ятканда, Шәмсия белән Хәлфетдин арасында нидер булганын сизеп алган иде. Хәлфинең, кеше-кара күрмәгәндә, әрсезләнеп, Шәмсиягә үрелгән чакларына да шаһит булды. Кулга алынганнарны каравыл йортына җыйдылар башта. Иң ахырдан Хәлфетдинне дә китереп яптылар. Беркөнне аның мактанган кебек: «Сәндерәдә урын ясадым, эт белән килеп эзләсәләр дә тапмалы түгел»,— дип сөйләнгәнен ишетеп калган иде. Ходайның амин дигән чагына туры килмәгәндер, килеп капкан бит әнә. Моңа Госман сөенеп тә куйды. Аннан һуш җыйгач, башкалар ишетмәслек итеп, Хәлфетдин белән ачыктан-ачык сөйләште. Хәлфетдин күтәрелеп бәрелмәкче иде дә, Госманның сабан тәгәрмәче кебек зур, түгәрәк йодрыгына, киң күкрәгенә, тәвәккәллекнең теге ягына чыккан карашын күреп, тиз суынды...

...Яшь хатын, Әхмәтсафаның тып итеп килеп керүен күреп, Хәлфидән читкәрәк тайпылды. Шулай да, үземнекен әйтеп бетереп калыйм дигәндәй, такылдап алды:

— Кире булсаң да булырсың икән,— диде ул, җан ачысы белән.— Бу шаукымнар үткәнче сәндерәңдә генә ятарсың. Курыкма, этем дә белмәс. Тайфә әби терелгәнче, ашарыңа үзем илтеп йөрермен. Шушы саташуыңны гына чыгарып ташла башыңнан.

Хәлфи астан Әхмәтсафага сөзеп карап алды.

— Тынычлан, сине эзләп килеп тә җиттеләр. Озакламый өйлә намазы... Хәзер үк китәм дигән кеше юк бит әле. Өйләдән соң гына, диләр...

## IV

Унтугызынчы елның язы үткән елгының нәкъ капма-каршысы булды. Апрель урталарында ук җир өлгереп, сукага чыктылар. Май урталарына Каргалы халкы чәчүләрне төгәлләп, күп эшләрен бетереп килә иде инде.

Бу ел сәүдә җәһәтеннән әллә ни уңышлы булмады. Дәүләтъяр нәселе борынгыдан бирле казакъ яклары — Тургай суы буендагы далага сибелгән кышлаклардан тире-яры җыеп, Оренбур, җай чыккан башка шәһәр-калаларга илтеп

тапшырып көн күрде. Шуңа күрә аларның нәсел кушаматы да Каеш иде. Әлеге кәсеп белән соңгы дәвердә җиң сызганып Мостафа гына шөгыльләнде. Кәсеп артык төшемле түгел, әмма җирне туфан басмаса, казакъ ягында мал бетмәс, тотрыклы эш санала, тормышлары да кеше алдында бөтенләй ким-хур булырлык та түгел иде.

Ибе килсә, җәбе килми, Мостафа хатын рәхәтен генә күрә алмады. Маһинур уңган, миһербанлы иде дә, көтмәгәндә вафат булды. Яшь хатыны Шәмсиягә никтер үзенең күңеле ятып бетми. Югыйсә, бөтен Тургай далаларын айкап чыксаң да, Сакмар буйларын иңләп йөрсәң дә, ахыр чиктә, көндез чыра яндырып эзләсәң дә табып ала торган бичә түгел. Шәмсиянең үз куенына килеп керүе Ходайның иң зур бүләге саналырга тиеш тә бит, юк, нәрсәдер тота Мостафаны. Ул аннан һаман тартыла, ачылып бетә алмый, шуңа күрәдер инде, назга, иркәләүгә сусаган хатынга көткәнен бирә алмый иде. Ничек дип әйтергә, Мостафа әле ир уртасы кеше, куәт тә, дәрт тә җитә юкса, әмма хатынны бөтен барлыгы белән үзенеке итеп тоя алмый. Ике арада ир белән хатын арасында гына була ала торган ышаныч юк. Ышаныч... Менә нәрсә җитеп бетми иде Мостафага. Әгәр тормыш иткәндә бер-береңә ышаныч юк икән, димәк, тормыш та юк дигән сүз. Ни гаҗәп, Мостафаның торган саен үзенә карата суына баруына Шәмсия һич тә борчылмый кебек. Эчендә утлар дуласа да, сиздермәскә тырышуымы шунда.

Тора-бара шуны сизде Мостафа — ул өйдә чакта сүрән генә йөргән яшь хатын, ире сәфәргә җыена башласа, гел үзгәреп бетә. Йөзе яктыра, йөгерек адымнар белән кече өйдән олы өйгә яки киресенчә күчеп-чыгып йөрүләрендә, балалар белән сөйләшкәндә, Мостафа белән үзара мөгамәләсендә дә пошаманга төшерерлек серлелек тоела иде. Андый чакта хатынын аңлый алмаудан гаҗиз калып, күңеленә әллә никадәр вәсвәсә тула. Бүген бичәсе тагын сәер холкын күрсәтеп алды. Тик бу юлы ир яшь хатынны аңлады кебек һәм, ни гаҗәп, шул минутта ук аңа җиңел булып китте. Шәмсия сугышта үлеп калган ире — Фәтхулласын оныта алмый, бичаракай. Күр, ничек өзгәләнә, ничекләр генә дә юатырга белмәссең. Дөресен әйткәндә, бу хисләр, шушындый ук кичерешләр Мостафага да ят түгел — Маһинуры кинәт күз алдына килеп, бәгырьләре киселеп куйган чаклар азмы әллә?

Уллары үсеп җиттеләр, таралып та баралар. Гомәрхан белән Госман кызыллар ягыннан сугышып йөриләр, исән генә була күрсеннәр берүк. Госман белән бергә яуга киткән Хәлфетдин озак та үтмәде, качып кайтты әнә. Үткер егет булып чыкты, шайтан. Моны аңа сер итеп кенә Тайфә карчык чишкән иде. Тик кайда качып ята торгандыр, анысын

әйтә алмый Мостафа. Тирә-юньдә гаскәрләр мыж килеп йөри, аны үзендә хезмәтче итеп тоту турында уйларга да ярамый. Бәхетенә, Әхмәтсафа үсеп килә. Ундүрт яшь инде аңа, чын егеткә әйләнеп бара. Уртача гәүдәле, киң җилкәле, бөркет карашлы егет булачак ул. Чәчү чорында Мостафаның күп эшләргә кулы да тимәде хәтта.

Чәчүләр тәмамланыр көннәрдә, Дәүли бай килеп керде. Дәүләтъяр нәселенә кагылышлы шәҗәрә агачының көчле ботакларыннан саналган кеше ул. Әхмәтсафаны казакъ далаларыннан мал куып алып кайтырга көнлекче итеп яллап китте.

— Эш сорап, тупсамның ишеген төшермиләр,— дигән иде ул.— Халыкка эш кирәк, берәү дә көнлекче ялларга атлыгып тормый...

— Аягың тәпердәмәсә, авызың чәпелдәми, анысы... Дөньяларның рәте китте шул. Үзем дә ай ярым казакъ арасында йөреп кайттым, үңәргән эшем булмады,— дип зарланып алды Мостафа.

— Дөньясы тынычланганны көтеп ятсаң, бөтенләй көяләп бетәрсең. Сәүдә хәле шундый, Мостафа туган, өстәп тормасаң, гомер буе җыйганны бер җәйдә туздырып бетерергә була. Госманны әйтәм, әрәм иттең гаскәргә язып. Сәүдә эшенә кулы килешә иде. Гомәр абзыйның кибетенә кергән саен кызыгып чыга идем. Шөкер, ди идем, Дәүләтъярныкылардан тагын бер төпле сәүдәгәр җитешеп килә, ди торган идем. Кайтып керсә, эшләре җайлы барган берәр сәүдәгәрнең кызына өйләндереп тә җибәрсәң!

Мостафаның бу сүзләргә күңеле булды. Шулай да сер бирәсе килми:

— Һи-и, Дәүли абзый, тумаган колынның билен сындырып куймыйк тагын,— дигән булды.— Әле үзе ни дияр! Чәче сәүдәгәр кызыныкына бәйләнсә, сәүдәгәр кияве булыр...

— Алай димә, Мостафа! — дип кырт кисте Дәүли.— Нәселеңне чүплисең килмәсә, егеткә тиңен табып бирергә кирәк. Үз тиңен таба алмаган кеше, иртәме, соңмы үкенә ул. Тик ул вакытта терсәкне тешләргә соң була инде. Егет кешене озак буйдак йөртү дә килешми. Башлы-күзле булгач, тагын да иҗтиһад кылып тотыначак сәүдәгә. Һай-ли, иҗтиһад итмәсәң булмый ул.

Мостафаның кәефе килеп, ипле тыңлап торуына инангач, үгезне мөгезеннән эләктерергә карар кылды:

— Әйтәм бит, халык бик килә эш сорап. «Ни бит, кем, туганкайлар,— мин әйтәм,— булмый, алдан ук вәгъдә иткән кешеләрем бар»,— дип, күбесен кире бора торам. Әхмәтсафаны алам көнлекчегә, каршы килмәсәң...

Мостафа, күрәсең, уйланып озаграк торгандыр инде, мо-

ңарчы өлкәннәрнең сүзенә катышмый, сабыр гына тыңлап торган Әхмәтсафа телгә килде:

— Барыйм, әткәй. Узган ел бер мәртәбә Актүбә ягыннан мал куыштым ич, эш рәтен беләм,— дигәч, каршы килмәде, түләү шартын килешеп, Дәүли белән кул сугыштылар.

Мостафаның исәбе буенча, Әхмәтсафа кичә өйгә кайтып керергә тиеш иде. Яңа көн туды, һаман күренми малай. Аның эче поша, бүген көн әллә ничек башланып китте шунда... Алмагачларына күз явын алырлык җете кызыл тасмалар бәйләп бетереп килгәндә, Мостафаның башыннан нинди генә уйлар чабышып үтәргә өлгермәде тагын. Менә шул чагында Шәмсия аны чәйгә чакырып чыкты да инде...

...Иртәнге чәйдән кузгалырга өлгермәделәр, өй ишеген киереп ачып, Дәүли килеп керде. Керә-керешкә, кәефенең көр булуына ишарә, гөлдер-гөлдер килә башлады:

— Кара әле, дим, Мостафа туган, бу чәчби кызың кемгә охшап шулай тыйгысыз, ә? Атны турыгызга туктатырга өлгермәдем, күктән яшен ташы китереп орды дип торам, синең кызың икән, арбага сикереп тә менде. Кай ара йокысыннан торган, кай ара урамга чыгып йөгергән! — Дәүли, йөзендәге елмаюын җыеп тормастан, шушы сүзләрдән соң гына кычкырып сәлам бирәсе итте: — Әссәламегаләйкүм, Мостафа туган, бәрәкәтү вә рәхмәтуллаһ.— Ул арада сәкегә капчыктай гына авып төште.— Аллаһ Тәгалә хәерле тереклек бирсен,— дип, дога кылырга тотынды.

Мостафа хәл-әхвәлләр сораша-сораша чынаякка чәй койган арада, Дәүли яңалыкларны тезеп тә чыкты.

— Шөкер, Мостафа туган. Әле кичә, караңгылар төшеп килгәндә, малларны алып кайтып җиткерделәр җегетләр. Ну, Мостафа туган, Әхмәтсафаң тырыш икән, бер дә башкалардан калышмады. Бер сарыкны расхудка чыгармыйча, кайтып җиттеләр бит.— Аннан нигәдер мал куучыларны мактаудан тыела төшеп, сүзне икенчегә борды.— Һи-и, гел шул тирәдә кайнаштым үзем. Бала-чагага ышансаң, җүләр... Үзе юкның, күзе юк, Мостафа туган. Таныш казакълар да ярдәм итте. Юкса кая мондый мәхшәрдә исән-имин кайтып җиткү. Менә генә бер җирдә сугыш кабынып китә, аны әйләнеп узасың, нәкъ каршыда туп гөрселдәргә тотына. Көтүне кая куарга белми аптыраган көннәр аз булмады... Ничек итсәм иттем, тәки исән-имин кайтарып җиткердем малларны. Акча, сәмән, дим, күктән яумый. Сәфәргә кузгалыр алдыннан дусишләрдән бурычка җыйдым сәмәнне. Кичә кич, өйгә кайтып аугач та, күзгә йокы керми, төне буе исәпләп чыктым. Йөрәктә кара сөлек утыра, Мостафа туган. Чыгым керемне басып китә.

Мостафаның, дөресен әйткәндә, Дәүлинең керем-чыгым дигән нәмәрсәсендә артык эше юк. Туган тиешле кешенең сәүдә эшләренә битараф булудан түгел, әлбәттә. Ул «брат братның көтү көтүенә рад» дип йөрүчеләрдән түгел. Кичә үк кайткач, Әхмәтсафа кайда икән? Шул уй борчый иде аны.

— Иртүк тордым да, тукта, мин әйтәм, Мочтайга кереп чыгыйм...

Күз алдында үз исемен бозып сөйләшүне өнәмичә, Мостафа кашын җыерып, сынап Дәүлигә карап алды. Бу карт төлке нәрсәдер майтарырга азаплана иде үзенчә.

— Синең малай Гомәр абзыйларда кунам, дип китте, малларны урнаштыргач. Өйгә кайтып кергәнме, юкмы, белмим. — Хуҗаның карашыннан Әхмәтсафаның өйгә кайтып кермәвен чамалап, тагын да җанлана төште. — Маллар Җаек аръягында, касапчылар ягында калды, — дип, сүзгә ачыклык кертеп алды.

— Арыгандыр инде, балакай...

— Арыган дип, алай артык ашыктырмадым мин аларны, үз көйләренә генә йөрттем... — Дәүли, кесәсеннән акча янчыгын чыгарып яны белән Мостафага борылып утырды да озаклап кәгазь акча кыштырдатырга кереште. Аның битенә сыек алсулык йөгерде, маңгаена тир бәреп чыкты. Санауны төгәлләгәч, тәвәккәл кыяфәт белән Мостафага акча сузды.

— Алып куй әле шуны, Мостафа туган. Әхмәтсафаның хезмәт хакы булыр бу. Бигайбә, менә саный башласаң, шулай бит ул, һич тә баштагы исәп барып чыкмый. Бераз киметергә туры килер инде, туганкай, авырга алма. Үзең дә әйткәнең бар, елларның бер дә рәте юк бит...

Мостафа, ничарадан бичара төстә, акчаны алып, ашъяулык астына шудырды. Дәүли исә чынаяктагы чәен шопырдатып чөмереп бетерде һәм ничек тиз керсә, шулай чыгып та китте.

Мостафа җавап кайтарырга кирәклеген исенә төшереп:

— Ходай ризалыгы өчен булсын инде, рәхмәт, Дәүли абзый, — дип кенә әйтә алды. Исенә килеп, кунакны озатырга дип, урамга чыккан иде, Дәүлидән җилләр искән. Мостафага аң керде. Дәүлигә Әхмәтсафа үзе кайтып кергәнче исәп-хисапны өзеп кую яхшырак иде. Мостафага нәрсә сөйләсә, шул дөрес. Чын эшнең кыйммәтен, маңгай тирен түгеп, үзе эшләгән кеше генә белә бит. Борынгылардан калган сүз бар: йорт сатучы янына килсәң, иң элек сора — бу йортны үзе салып кергәнме, әллә әткәсе төзегән өйне сатарга җыенамы егет? Әткәсе төзегән йорт булса, курыкмыйча сөйләшергә була, егет йортны үзе җиткерсә — якын да килмә, аңа өйнең һәр чөенең ничек кагылуы мәгълүм, бәясен дә сорый беләчәк инде ул!

Киртә башына үрмәләп менгән Бибиҗамал, әткәсен күрүгә, сөенеченнән кош тоткандай:

— Әткәй, кара әле мин кайда мендем! — дип, ике кулын да җибәреп, киртәгә аягүрә басарга маташа башлады. Мостафа тиз генә барып, кызын киртәдән йолкып алды, аның җылы ак муенын үзенең чал керә башлаган сакалы белән кытыклый-кытыклый, өйгә атлады. Кыз чырык-чырык көлә, Мостафага да рәхәт булып китте.

Кергәч, акчаны санап карады. Дәүли сөйләшкәннең яртысын калдырып чыгып киткән икән.

* * *

Кайда ятканын да белмәде Әхмәтсафа бу төнне. Ун-унбиш көн ачык далада учак ягып, иптәшләре белән алмаштилмәш черем итеп төн үткәрүләр, кояш белән кузгалып, туктаусыз «һай-һу»лап мал куа-куа алга барулар аны тәмам йончыткан иде. Гомәр абзыйларына ничек килеп кергәнен дә, аңа урын салып биргәнче, инде йокы базарына китеп баруын да җүнләп хәтерләми бугай... Шул ятудан кояш күтәрелгәнче тора алмый ятты. Әйтерсең кемдер рәхимсез тукмап ташлаган — аяк-кулларны кыймылдатып булмый, бөтен тәне ватылган, күз керфекләре эренләп ябышып беткән, әле уянып торырга ниятләгәч тә, күзләрен ача алмый җәфаланды ул. Кузгалып китеп, ныклап юынгач кына кеше рәте керде аңа.

Гомәр абзый ашыкмый ашап утырган Әхмәтсафага үз итеп карап алды. Кай арада үсеп җиткән диген! Кулыннан эш килер егеткә охшый Мостафаның бу малае. Үсмернең хәленә кереп, дәшәсе итте:

— Вәйт, агай, кара-чутырга әйләнгәнсең син, ә?! Өеңә кайтып керсәң, ай-һай, таный алырлар микән? Әллә соң, мин әйтәм, берәр атна шәһәрдә калып, көч җыеп аласыңмы?

Әхмәтсафа, йөзендәге җитдилеген җуймый, башын чайкап куйды. Шушы аз гына хәрәкәттән дә муен тирәләре әрнеп сызлый башлады. Бөтен тәне җәрәхәттән торадыр сыман тоела иде аңа хәзер.

— Юк инде, агабзыкай (Ак абзыкай, ягъни укымышлы, зыялы дигәне), өйгә кайтам,— диде ул, иреннәрен сак кына кыймылдатып.

Гомәр абзый көлеп җибәрде.

— Каргалы кичә үк күчә башлаган, диләр иде, тизрәк кайта күр, бөтенләй Сакмар артына күчеп бетмәсен.— Аннан җитдиләнә төште: — Кайтырсың, Алла колы, кая ашыгасың? Ашаганнан соң бераз ял ит. Бездә сиңа ярашлы кием бетмәгәндер, өс-башыңны алыштыр, бөтенләй сәләмәгә әй-

ләнгәнсең, җегет кеше шулай буламы? Онытма, без — Дәүләтъярныкылар! Кеше күзенә чәчрәп керергә яратмасак та, ил-көн алдында ким-хур булып йөрүне дә хупламыйбыз. Шөкер, нәселдә бер генә адәмнең дә юк-бар эш белән йөреп вакыт уздырганын, нәселне дегеткә буяп йөргәнен күргән юк,— дип, Әхмәтсафаны олы якка әйдәде.— Кер әле монда. Әбүгалисина мәгарәсе булмаса да, искитәрлек нәрсәләр бар монда,— дип, бүлмә диварына беркетеп ясалган китап киштәләренә күрсәтте.— Байлык менә кайда ул. Безнең халыкның рухи байлыгы монда, энем. Укы гына, белемле бул, милләткә хезмәт ит. Синең максатың шул булырга тиеш!

Бүлмә салкынча, бераз караңгырак иде, эссе кояшта тилмереп, җек күргән тәннәр иркен сулыш алган кебек булды. Чыннан да, үзеңне серле мәгарәдә сыман хис итәсең — пәрдәләр китапларга кояш нурлары төшмәсен диптер инде, нык-лап тартып, томалап куелган.

Гомәр абзый бүлмәгә ут элде, киштәдән бер китап алып, аның битләрен актаргалады да Әхмәтсафага күтәрелеп карады:

— Гаяз әфәнде Исхакыйны беләсеңме?

Әхмәтсафа нигәдер каушый төшеп, ләкин үз-үзенә ышанып җавап кайтарды:

— «Сөннәтче бабай», «Теләнче кызы» дигән әсәрләр язган кешеме?

Хуҗаның йөзе яктырып китте.

— Күз тимәсен, Мифтах хәлфә сезгә төпле белем биреп ята түгелме соң?! Әйе, Гаяз әфәнде әсәрләрен санап киттең син. Бер нәрсә уйлап, сүз әйтә икән, шул сүзеннән үлсә дә кайтмый инде. Холкы аркасында күпләргә ярап бетмәсә дә, милләтне алга, тәрәккыяткә җибәрү өчен аннан да күп эшләгән әдип юктыр...

— Тукай, Әмирхан, Ибраһимов, Рәмиев?..— дип, сораулы карашын әңгәмәдәшенә төбәде Әхмәтсафа.

— Исең китәр! — хисләнеп, кулын өскә күтәрде Гомәр абзый.— Шушы сәләмә киемгә төренгән егет кисәге әдәбиятымызның биниһая якты йолдызларын санап чыкты. Син аларны укып беләсеңме, әллә болай, ишетепме дигәндәй...

Әхмәтсафа кинәт калкынып куйды һәм көтелмәгән ачык тавыш белән шигырь укый башлады:

...Әрни-әрни ләгънәт әйтәм,
Тискәре бу дөньяга.
Мин мәхәббәт нуры дим, ул
Аерылу шәмен яга...

— Афәрин, балакай! Әйтеп бак, кем булыр әлеге тетрәткеч юлларны язган шагыйрь?

— Сәгыйть Рәмиев,— диде Әхмәтсафа. Ул инде үзен имтихан вакытындагы кебек хис итә иде. Җавап тотучы халәтенә керешеп, уй-фикерен бер нәрсәгә — әдәбиятка туплады. Яшереп торасы юк, ул нәсер, шигырь язучыларга сокланып бетә алмый, аларны гайре табигый адәми затларга саный иде. Аның өчен иҗат, шагыйрь, әдип кебек төшенчәләр изге, ул әдәбиятка мөкиббән иде.

Моны Гомәр сәүдәгәр дә сизеп алды, ахры. Сәгыйть Рәмиевның шигырен ишеткәч, кош тоткандай, сөенеп, әңгәмәдәш табылуына канатланып, сүзен дәвам итте:

— Әйе, энем, әдәбият кешегә күп акыл бирә. Аны дөрес итеп кабул итә белергә кирәк. Менә Сәгыйть әфәнде адәм баласының дөнья белән каршылыкка керүен, уй-хисләрендә алдануын ни рәвешле ярып салган. Тик әдәбиятымыз зур безнең, син санап үткән әдипләрдән башка тагын бөекләремез бихисап. Бу хакта белү кирәк, җитеп киләсең, нәкъ акыл җыя торган чагың. Мәрҗани хәзрәтләрен беләсеңме?

— Ишеттем...

— Ишетү генә аз, һай, бик аз, энем. Мөселманга намаз фарыз булган кебек, татар шәкертенә Мәрҗани хәзрәтләрен белү фарыз. Тагын бер карт әдибебез бар — Риза Фәхретдин хәзрәтләре...

— «Сәлимә» дигән әсәрен укыдык,— диде Әхмәтсафа, куана төшеп. Аның белексезләнеп бер дә Гомәр абзыйсын рәнҗетәсе килми иде.

— Рәхмәт төшкере, димәк ки, Риза хәзрәт иҗаты белән азмы-күпме таныш инде син. Мин кайсы әдип белән сөйләшсәм дә, гел әйтә киләм: «Әдәбиятымызда Риза Фәхретдин хәзрәтләрен читкә алып куеп булмый»,— дим. Яңа әдәбият дип шаулап йөрүчеләр күп ул, ә Риза хәзрәт бер «Сәлимә» әсәрен генә язса да, мәңгелеккә кереп калыр иде тарихымызга. Менә ул кайда бөеклек, менә ул кайда милли рух, халык тормышын эченнән үк аңлау, аны шәкертләремезнең башына сеңдерерлек куәт белән яза алу. Укы, энем, Дәүләтъярныкыларга, әйтмәсәм дә булмады, гомер бакый «каеш» булып, касапчылык, тире-яры белән генә эш итәргә димәгән, гыйлем юлы белән дә бару фарыздыр...

* * *

Каргалыга кайтырга чыккач, Сакмар тавыннан төшеп, күпергә якынлашып килгәндә дә, Әхмәтсафаның башында Гомәр абзыйның хикмәтле сүзләре бөтерелә иде. Алар җилкетә, алга әйди, үсендерә, шушы сүзләрдән соң яшәүнең мәгънәсен чамалаган сыман булды, күңел түреннән җанны ымсындырып нинди дер яктылык өермәсе үтте. Уйларына йо-

тылып бетеп барганда, каршысына әллә каян гына Тайфә карчык килеп чыкты.

— Әхмәтсафа балакаем, син икәнсең әле. Таный алмыйча йөдәдем. Тау сыртында каршыга килүче бер гәүдә күренгәч тә, кем булыр, мин әйтәм, бу хәтле пошмый гына атлаучы. Хәзерге кешене белмәссең, карчык-корчык дип тормас, мин әйтәм, кулымдагы төенчеккә күзе кызып, Аллам сакласын, бер-бер хәл кылмагае дип, әрәмә арасына кереп, посып тордым. — Тайфә карчык, сер әйткәндәй, бөкерәя төшкән гәүдәсен як-якка боргалап, якын-тирәдә чит кеше юклыгына тәмам ышанып беткәч кенә, Әхмәтсафаның күлмәк җиңеннән чак кына эләктереп, үзенә тарта төшеп, яңа хәбәр әйтеп салды: — Балакаем, әле генә олы юлдан авылга мылтыклы гаскәр кереп калды. Гөрс тонып, шау-шулап баруларына караганда, кызыллар булса кирәк. Мин башта олы юлдан барадырыем, аларны әрәмә арасына качып үткәреп җибәрдем дә шушы кыска юлга төштем. Мәгәр, алда баручы башлыклары узган ел малайларны армиягә алып киткән адәмгә охшаганые. Хәлфетдин белән Госманны әйтәм инде. Гомеркәе булгач, Хәлфетдин Ташкентка барырга чыккан җирдән пуездан төшеп калган. Госманнан бер-бер хәбәр юкмы?

— Юк иде әле, Тайфә әби. Китте дә батты. Әткәй борчылып, төн йокылары йоклый алмый инде. Мин киткәч кенә хәбәр бирмәсә...

— Шәмсияне күргән ием, хәбәр-мазар булмады, ди. Рәхмәт инде, Шәмсияне әйтәм, хәлне белеп кенә тора. Әле бүген дә аңа ышанып калдырдым өйне. Үзем Оренбурга, олы кызым янына барып кайтырмын дип юлга чыкканыем. — Тайфә карчык, сүзенең кереш өлеше тәмамлануга сөенгән кебек, тагын як-ягына җәһәт каранып алгач, күңелен кыздырып торган серен әйтеп ташлады: — Хәлфетдин абыеңны әйтәм, лапастагы сәндерәдә качып ята хәзер. Шунда ясаган иде яшерен урын. Сандык инде, сандык. Булса да булыр икән шулай эшкә оста кеше. Әрәмнәр булмаса ярар иде балакай. Котларым очып тора, дус бар, дошман бар, берәрсе тишеп, каптырып алмасалар ярарые Хәлфетдинемне. Алай күргәнбелгән кеше юк сыман әлегә. Безнең өй, шөкер, хәллерәк бәндәләрнең ихаталары арасына кысылып, күзгә-башка артык бәрелеп тормый. Аннан шул бәләкәй генә йортта имәндәй таза җегет качып ята дип кем уйлый инде, иеме, улым?.. Хәлфетдин үскәндә и шаярып җибәрә торганые, балакаем. Атасыз үскән малай тынгысыз була бит ул. Йөрәгем урыныннан куба торганые инде, саманнан корыштырган стенага ялгыш килеп бәрелеп, йортны ишеп төшерер дип. Алла саклады инде, исән була күрсен. «Сине сагынып кайттым, инәй,

сагынуга түзеп булмый икән», — ди наныем. Госманны әйтәм, кайларда, нинди михнәтләр чигеп йөри торгандыр...

Әхмәтсафа, Тайфә карчыкның озакка сузыла башлаган сүзеннән ялкып, кузгалмакчы булган иде, карчык, каударланып, каршысына ук төште:

— Туктап тор, улым, бер генә сүзем калды. Хәлфетдинне әйтәм, сәндерәдә бер-бер эш белән мавыгып китмәсен дим. Балта сабы юнып азаплана иде. Зинһарлар өчен, кайтышлый сугылып кит, хәбәр сал, авылда солдатлар барын белеп торсын дим...

Тайфә карчыкның гозерен үтәргә вәгъдә биреп, Әхмәтсафа авыл ягына ашыкты.

Өйдә хәзер нишли торганнардыр. Госман абыйсыннан һаман хәбәр килмәве һич тә яхшы түгел шул. Җитмәсә, Хәлфетдине тагын... Искәрми калып, кызыллар кулына төшмәсә ярар иде. Инде Әхмәтсафа белә — шома сөйләсәләр дә, кызыллар килеп керсә, авылга бигрәк күп бәла-каза китерә. Алар авызыннан туктаусыз сибелгән ирек, җир, бәхетле тормыш кебек сүзләрне тыңлый башлагач, әллә соң, чыннан да, бәхетле, матур тормышка чыгу өчен шундый аяусызлык, беркемне дә җәлләмәү, беркем белән дә хисаплашмау кирәк микән, дип уйлап куясың. Эссе дала кояшы астында мал куып, әлсерәп, хәлдән таеп егылыр чиккә җиткән чакларда да шул талкый иде җанын.

Әмма бер гөнаһсыз кешеләрнең канын коюны ул берничек тә аңлый да, аңлата да алмый иде.

...Ул авылга килеп кергәндә, Яңа мәчет тирәсенә халык җыйнала башлаган иде. Әүвәл өйләренә кереп чыгасы килсә дә, Тайфә карчыкның үтә пошаманга төшеп әйткән сүзләренең тәэсире зур булдымы, урам чатыннан күренеп торган акшарлы биек йортка, ягъни үзләренә табан түгел, тыкрык түренә посып утырган Тайфә карчык өенә борылды.

## V

Мөселман полкының Оренбурдагы беренче төне тыныч үтте. Иртәнге аштан соң, гаскәрләрнең ничек урнашуларын, кәефләре кай чамада икәнлекләрен белү максатыннан, Усманов полк биләмәләрен урап чыгарга уйлады. Киенеп бетәргә өлгермәде, кемдер сабырсызланып ишек шакыды һәм рөхсәт көтеп тормастан, каерылып ишек ачылды. Бусагада Еникеев күренде. Ул полкта культура-агарту эшләре өчен җаваплы. Кичә соң ятуына карамастан, таң тишегеннән аяк өстендә, шәһәрне саклаучы гаскәрләрнең үзәк штабында булырга өлгергән. Усманов үзенә буйсынган командирның аннан алда җитешүенә бераз күңеле кителсә дә сиздермәде.

Мондагы командование Еникеевка артистлар белән концерт кую эшләрен башлап җибәрергә фәрман бирергә өлгергән. Киңәшкә Усмановка йөгергән — монысы өчен комиссарның күңеле булды, әлбәттә. Оренбурны саклауны оештырган җирле хакимият әле полк командирлары белән танышып өлгермәде, кемнең кем икәнен белеп җиткерми, шуңа күрә, кичә төштән соң шәһәргә килеп кергән бер полк гаскәр аларны канатландырып җибәрсә дә, шундук үгезне мөгезеннән эләктерергә телиләр, килгән гаскәрләрне үз кул асларына алып, монда кем өстен, кемнең фәрманы белән эш итәргә тиешлеген аңлатырга маташалар, ахры. Кемнең кемгә буйсыну мәсьәләсе гаскәрләр өчен үтә мөһим һәм әгәр вакытында хәл итеп өлгермәсәләр, бу четерекле нәрсәгә әверелергә мөмкин иде. Мәсьәлә җитди, аны тиз арада хәл итәргә кирәк тә, тик Оренбурдагы иптәшләр үзләренчә уңай юл тапканнар: күзләренә кайсы командир чалына, нинди дә булса ашыгыч фәрман биреп, аның тиз арада үтәлүен таләп итәләр, кемнең кем икәнен белегез, янәсе. Теләсә ничек тупланган партизан отряды белән эш итәләрмени?! Юк инде, туганкайлар, каршыгызда регуляр кызыл гаскәр тора, тәртипкә күнә башларга туры киләчәк.

Усманов, бу хәлнең буласын алдан чамалаганга, елмая төшеп, Нигъмәтне тынычландырырга кереште:

— Фәрман икән — фәрман, үтәрбез. Тик алар әйткәнчә ашыгып түгел. Артистларның программасы белән танышыйк, шуннан соң аны полк штабы расларга тиеш. Беренче чыгыш артистлардан җаваплылык таләп итә. Кайда, кемнәр алдында беренче мәртәбә сәхнәгә чыгалар, тамашачы аларны ничек кабул итәчәк? Болары да мөһим. Үзәк штабка үзем барып, барлык мәсьәләләрне хәл итеп кайтырга туры килер. Бу хакта полк командиры да уйлана, штаб утырышында үз сүзен кистереп әйтәчәк дип уйлыйм. Оренбурдагы иптәшләрнең зиһеннәре таралып китте бугай. Кем нәрсә куша, шуны үтәп йөрергә, без монда йомышчы малайлар командасын алып килмәдек. Шәһәргә йолкышлар отряды түгел, регуляр Кызыл Армия частьлары, ягъни 1 нче татар укчы полкы килүен тизрәк төшенсәләр, яхшы булыр иде.

Әлеге сүзләр Нигъмәт Еникеевның күңеленә ятты. Усмановка карап, көр тавыш белән өстәп тә куйды.

— Үзем дә шушы караштa торам, иптәш комиссар.

— Яхшы. Алайса киттек. Иң элек штаб урнашкан вагонга кереп чыгыйк, — дип, Усманов эре-эре атлап чыгарга юнәлде. Нигъмәт, бер читкә тайпылып, аңа юл бирде.

Полк командиры шәһәрне саклаучы үзәк штаб вәкилләре белән кичә очрашкан икән, мондагы вазгыять хакында шактый хәбәрдар булып чыкты. Бу тирәләрдә күптән тү-

гел генә колчакчылар белән сугышлар булып узган. Хәлиткеч бәрелеш Каргалы авылы тирәсендә булган. Сугыш сугыш инде, халык өчен дә эссез калмаган. Күп кан коелган, йорт-куралары зыян күрүчеләр дә байтак. Уйланырга мәҗбүр иткәне — авыл халкы кызыллар килүгә риза булмыйча, җыен үткәреп маташкан. Гаеп, билгеле, кызылларның үзендә. Дорфа кыланганнар, талаганнар, туздырганнар, көчләгәннәр... Гаеплеләргә тиешле җәза бирәсе урынга, командирлар аларны яклау юлына баскан. Бу хәл халыкны отыры котыртып җибәргән. Хәзер шушы гөнаһны юу мөселман полкы өстенә төшә икән. Актүбә ягына чигенгән колчакчылар теләсә кайчан Оренбурга яңа һөҗүм башларга мөмкин. Тылда кызылларга ачулы, шәһәргә биргесез зур саланың булуы полк командирын борчуга салган иде. Өмет бар — полкта үткән яз Каргалы халкы алдында аз-маз гына булса да абруй казанып өлгергән Усмановның булуы, җитмәсә, полк белән бер бригада артистларның да килүе үзәк штаб җитәкчеләренең күңеленә дәрт өстәгән икән. Үзәк штаб киңәшен тотып, артистларга тәүге концертны Каргалы халкы алдында күрсәтергә фәрман бирелде.

Бригада солдатлар озатуында Каргалыга кузгалды. Үз араларында Усмановның булуына труппа кызлары сөенеп туя алмыйлар иде. Кызларның барсы да диярлек аңа гашыйк, ул үзе дә җебеп йөри торганнардан түгел, кызларга караш ташлауга ук коңгырт күзләрендә шаян очкыннар уйнап ала. Ат өстендә ипле, көяз утыруларын гына күр син аның! Комиссарның кызып киткән чакларын күргән кызлар аннан бераз шүрлиләр, шулай булса да аның кайбер чакта бөтенләй малай-шалайга әверелә язып үзләре тирәсендә бөтерелә башлавын көтеп кенә торалар. Һәр репетициягә диярлек килеп, артист халкына хәленнән килгәнчә ярдәм итәргә тырышуыннан да разый иделәр. Шуңа күрә дә Каргалыга килеп җиткәнче, колонна өстендә көлешү, шау-шу тынып тормады.

* * *

Әхмәтсафа, авылга кайтып кергәч, аруын онытты. Күңелендә малайлык шаяруы уянып, Тайфә карчыкларга урам як капкасыннан түгел, ә читән белән лапас арасындагы аралыктан мәче кебек шылт иткән тавыш чыгармый үтте. Урам яктан керә калса, качып-посып йөри торгач Хәлфетдин шактый шомарган, «кемнең кем икәнлеген аяк атлавыннан чирек чакрымнан таныйм» дип мактанганы да бар, бәлки, Әхмәтсафаны танып та алыр иде. Таный калса, кызык булмый инде ул. Үсмернең күзе очлы — авыл эргәсендә сугыш барган куркыныч көннәрдә, үги әнкәсе Шәмсиянең яшертен ге-

нә Хәлфигә берничә мәртәбә ашарга илтеп кайтканын күреп калган иде. Бу хакта аннан башка беркем дә белмәде бугай, хәтта әтисе дә бихәбәр йөрде, ахры.

Әхмәтсафа сак кына лапас эченә үтте. Салкынча лапас эченә кергән уңайга шаяртасы килү теләге сүрелә төшеп, әкрен генә сызгырмакчы булды. «Аң бул, Хәлфи, без килдек», имеш. Әмма ирен арасыннан ул көткән «фью-үү-ү» чыкмады. Хәтта үкенеп куйды: кипшегән ирене чатнап ярылып, әрнеп сызлый башлады. Ул барсына кул селтәп, лапас түренә, Хәлфи абыйсы кайчандыр осталык белән, кеше күзенә тиз генә чалынмаслык итеп ясаган сәндерә  тарафына икеөч адым атларга өлгермәде, шып туктап та калды. Сәндерә ягыннан тыенкы көлү, чыш-пыш тавышлар ишетелде. Үсмер сагаеп калды. Хәлфи үз-үзе белән сөйләшеп, көлеп, җүләрләнеп ятмый торгандыр бит инде, ачуым бер килмәгәе? Булса да булыр, елга якын шулай кешедән кача-поса җан асрый бит ул. Чордашлары бер якка да кушылмый йөрделәр-йөрделәр, дә, болай кан калтырап яшәгәнче, ни язган булса шул булыр, дип, йә аклар, йә кызылларга кушылып, сугыш юлларына кереп югалдылар. Хәлфи бирешми әнә: «Инәкәемне сагынып кайттым»,— диде дә, вәссәлам, яшеренеп ята бирә. Хәлфине кызганып куя иде Әхмәтсафа. Үткән ел, атылудан исән калгач, әллә сөенечтән, әллә һушларына килә алмый әнкәсе Тайфә карчыкның ай-ваена карамый тәвәккәлләгән иде ул. Башка егетләргә: «Кызылларга язылабыз, малай, болай йөрсәк, куяннар урынына чүкеп бетерәләр безне», — дип,  кызып-кызып сөйләнеп торганын да ишеткән иде. Тик шунсы гаҗәп тоелды, Хәлфи бер сүз әйткән саен, дөрес сөйлим микән дигәндәй, Госманга күз салып ала иде... Үги инәй Шәмсия егетнең ниятен белгәч, Әхмәтсафа үз күзләре белән күрде, Хәлфинең муенына сарылып, кан-яшь койды...

Сәндерәгә тар баскыч сөяп куелган. Үсмер  бер арата күтәрелмәде, сәер аһылдаулар ишетеп, тукталып калды. Юк, бер дә Хәлфинең ялгыз эшсезлектән, эч пошудан ыңгырашып, аһ-ваһ килеп ятуына охшамаган бу. Татлы, тансык, көтеп алган рәхәт чигүгә тартым авазлар ишетелә монда. Хәлфи янына  йә Әхмәтхан килеп менгәндер дә, савыгуына сөенеп, уйный, шаяра торгандыр. Әле ярый сәндерә хакында Биби белми. Ул булсамы?! Лапас эчен генә түгел, бөтен урамны яңгыратыр иде.  Әхмәтсафа хәзер генә арыганын тойды. Ул әнә егерме чакрымлап җәяү атлап кайтты, Хәлфине кисәтәм дип, монда килеп җитте, ә егет кисәге дөньясын онытып кем беләндер көлешеп-шаярып ята. Болай гөманлап торганчы, кем булса да барыбер түгелмени соң, ул сабырлыгы бетеп, бертында өскә үрмәләп менде һәм тартма рәвешендә эшләнгән сәндерәнең читенә килеп сарылды...

Күз аллары караңгыланып китте. Күзенә чалынган күренештән Әхмәтсафа телдән язып тора иде. Кадаклап куйганнар диярсең, кире сикереп кенә дә төшеп китә алмый, сәндерәгә менеп үк тә җитә алмый. Тартма читенә ябышты да калды. Сәндерәдә үги әнкәсен һәм Хәлфине шәйләп алды ул. Шәмсия шулай кисәк пәйда булып, үзләре өстенә капланган кара-чутыр кеше затын күреп, өстендә яткан Хәлфине чөеп кенә җибәрде. Әхмәтсафаның кулына үги әнкәнең шәрә боты тиеп китте, битен ялмап алган итәк җилен тоеп алды. Хатын «аһ» итәргә генә өлгерде, ниндидер көч аны үсмер аша биеккә үк чөеп җибәрде дә, тагын бер аһылдап алган арада, лапас эченә дөбердәп килеп тә төште. Җилләнеп, шашып урыныннан сикереп торган шәрә Хәлфетдин, аптыраудан бөтенләй кыяфәтсез калган бәндәдә Әхмәтсафа чалымнарын шәйләп, селтәнеп торып, үсмернең күкрәгенә китереп төртте. Әхмәтсафа түбәнгә очты. Ул исен җыеп, мәрәләп аягына күтәрелгән арада, кай арада күлмәк-ыштан киеп өлгергән диген, шаулап Хәлфи сикереп төште һәм тәмам аңгыраеп калган Шәмсияне күтәреп торгызды:

— Авыртмадымы, җаным?.. Ник лапас keләсен элеп кермәдең инде? — диде ул, тонык тавыш белән. — Шулай сикерәләр димени. Кем дип белдең, ул хәтле... — Ул ачу белән Әхмәтсафаның иңсәсеннән эләктереп алды. Үсмернең күлмәге аерылып чыкты. Хәлфи еламсыраган тавыш белән аңа укталды: — Ни калган сиңа монда? Нәрсә дип йөрисең? Болай да кешелегем калмады... Хәзер нәрсә була инде? Йә?

Нәкъ шушындый ук сораулар үги инәйне дә газаплый иде, ахры, ул, чайкала-чайкала, түргә табан берничә адым атлады һәм лапас почмагына башын төртеп үкси башлады.

— Бар икән күрәселәр... Адәм хуры булдым би-ит. Язга чыккач ук әйттем мин сиңа, китик, күзебез кай якка карый, шул якка чыгып китик, дип әйттем... Үги балалар багып кем рәхәт күргән?.. — Хатын кайчандыр Хәлфи белән булып алган бәхәс-сөйләшүләрен исенә төшереп такмаклый иде.

Ярым караңгы лапас эчендә дә Хәлфинең тирләгән, кызарган йөзен аермачык күрде Әхмәтсафа. Егетнең исә үз хәле хәл. Кызганыч итеп бертын хатын ягына карап торгач, авыр сулап телгә килде. Егет һушлы, бу очракта иң беренче хатынны акылына китерергә кирәк иде. Әкрен генә сүз башлады:

— Кирәкми, Шәмсия, юкка яшь койма. Әхмәтсафа малай-шалай түгел, барсын да аңлый. Шулай бит, энекәш! — Ул ниндидер кыргый, ярсулы караш белән үсмергә төбәлде. Әлеге караштa: «Әгәр монда күргәннәрне кемгә дә булса җиткерсәң...» — дигән янаулы мәгънә ярылып ята иде. Егет хәтәр җилләнеп тагын Әхмәтсафага ябырылды. Үсмер

исә һич кенә лапастан чыгып таю җаен таба алмый, Хәлфинең киң күкрәге ишекне томалап торган кебек.

Шәмсия, эшнең тагын да аянычрак борылыш аласын сизеп, кисәк хәрәкәт ясап итәген тарткалап алды һәм эчке бер ярсу белән Хәлфигә дәште:

— Тиясе булма! Барысына да мин үзем гаепле. Мине ни эшләтсәң дә эшләт, тик аңа кул күтәрмә!

Хәлфи, башын сәер чайкап, ишек яныннан читкә тартылды.

Шәмсия тагын аһылдап алды.

— Кабыргам сынды бугай...— диде ул, үкенүле тавыш белән.— Сәндерәдән таштай очып кына төштем бит. Исәр димә инде мине. Күрәчәгем булгандыр, бүген бер дә аягым тартмаган иде...

Бу сүзләрдән Әхмәтсафа шуны аңлап алды: димәк, үги инәй монда башка көннәрдә дә булгалый икән. Ул әле һаман, берни аңламаган сабый сыман, башында бөтерелгән сораулардан гаҗиз калып тора иде. Ни калган аңа монда, нәрсә эшләп йөри ул Хәлфи янында? Хәлфиен әйтерием, ник җенләнә ул кадәрле?..

Хатын исә вазгыятьне үз кулына алып, хәлне бераз йомшартырга тели иде. Әхмәтсафаның күңелен табарга теләгәндәй сөйләнә бирде:

— Кинәт баш очымда кара-чутыр бер нәмә күренгәч котым очты. Җен дип торам. Болай да куркып яткан... кешегә соң...— Ул тынычланып җитә алмый әле. Теленә ни килә, шуны сөйләп, эшне бозып кую ихтималын сизеп алды. Ипләп кенә сүзне башка якка бора башлады.— Коймак пешергән ием. Дәүли абзый: «Әхмәтсафа бүген кайта»,— дип кереп әйткәч. Хәлфетдин абыеңа да илтеп кайтыйм, мин әйтәм. Кайчаннан бирле җылы аш күрмәгән кеше бит.

Хәлфетдиннең дә йөзе яктыра төште. Һи-и Шәмсия, хәйләкәр хатын! Борчакны пешерә болай булгач.

— Ни булган соң әле монда, әйеме, үскәнем? Хәлфетдин белән сөйләшеп... утырган җирдән, искә-санга алмый торганда килеп чыктың бит. Кеше күрмәсен дип, Хәлфетдин мине үз янына суырып кына алды.

— Ыгы-ы...— Хәлфетдин сөенеп көлеп куйды.— Шулай булды инде. Куркыта бит инде. Бу хәлләрне оныт, Әхмәтсафа энекәш. Ни күрсәң, шуны дөньяга сибеп йөрү егетлек түгел ул...

— Юк инде, нишләп кешегә сөйләп йөрсен! — дип юхаланып алды Шәмсия.— Балалар арасында иң акыллысы, иң яратканым шушы Әхмәтсафа. Төшкән көннәремдә, өйдәге чисталык, тәртипкә исем киткән иде. Өйне җыештырып, балаларны карап торучы — ул булган.

Үги инәй кабыргасы авыртуын да онытып сөйли дә сөйли. Ничек тә Әхмәтсафаның күңелен күрергә тырышуы үзенчә.

Хәлфи тәмам тынычланды дияргә була.

— Шәп егет булып үсә, энекәш, — диде ул, баштагы дорфалыгы өчен гафу үтенгәндәй. — Әле өенә кайтып кергәнме, юкмы — минем хәлне белешергә килеп җиткән. Түлке, энекәш, болай тавыш-тынсыз, мәче кебек өскә килеп кермә бүтән. Ни булмас дисең?..

— Кайчан кайтып кердең соң? — дип, төчеләнүен дәвам итте Шәмсия. — Өйгә кердеңме, әткәң өйдәме?

Әткәсен телгә алгач, Әхмәтсафа бөрешеп калды. Хәлфи белән Шәмсиянең көтмәгәндә калган кыен хәлдән чыгарга маташып әртисләнеп торулары күңел болгаткыч тәэсир ясый иде. Шушы яшь хатынга ышанып йөргән әткәсенең зарлы карашын күргән кебек булды. Шушындый авыр, аңлаешсыз заманда көткән дөньясын пыран-заран китермәскә тырышып йөрүче, миһербанлы, нечкә күңелле әткәсе кызганыч, бик кызганыч тоелды аңа.

Үги инәй, кулын күкрәк тирәсеннән алмый, тагын бер мәртәбә Хәлфигә яндыргыч караш ташлады:

— Ишетсен колагың, тырнак очы белән чиртәсе булма Әхмәтсафага! — диде ул, һәм, җавап көтмәстән, лапас эченнән чыгып йөгерде.

Шәмсия чыгып киткәч, Хәлфетдин бөтенләй басынкыланып калды. Әхмәтсафаның гәүдәсе базык булса да, көч-куәт ташып тора. Хәлфетдиннең исә кайчаннан сәндерәдән төшкәне юк. Эшсезлектән, хәрәкәтсезлектән тәне сизрәп бара. Үсмер алдында бая харап кыланган булса да, бергә-бер чыкканда Әхмәтсафа тиз генә бирешердәй күренми. Нәкъ шуны искәрткәндәй, Әхмәтсафа артык коелып төшмичә генә сүз башлап азаплана әнә:

— Кызыллар килгән авылга. Яңа мәчет тирәсендә кайнашалар. Шуны әйтеп китим дигән идем дә...

Хәлфи сагаеп калды.

— Ни эшләргә соң миңа, энекәш? Бала-чага түгел икәнеңне беләм, дөресен әйтәм, Шәмсия белән...

Әхмәтсафа, җуләр сатма дигәндәй, кинәт алга тартылды.

— Беләбез! — диде ул, нәфрәт белән. — Госман абый да белә... Бу хакта онытасы килә иде. Сез һаман хыянәт юлында икәнсез.

— Менә бит, аралар ничек булып бетте... — диде уфтанып Хәлфи.

— Имансыз булдың, Хәлфи. — Үсмернең бу җирәнгеч затка абый дип дәшәсе килмәде. — Икегез дә, — дип тә өстәп куйды. — Әткәй кызганыч... Сез — аның намусын таптаган хайваннар. — Әхмәтсафа торган саен кыза барып, чын-

чынлап һөҗүмгә күчте.— Ни кыланганыгызны әткәй белеп алса, икегезне дә балта белән тураклап өячәк!

Хәлфи аклануга күчте:

— Мостафа абзый юаш күренә шул. Шәмсия шуңа күрә ашкынды да инде. Ничек булгандыр, үзем дә сизми калдым, энекәш, шул хатын тәки аздырды бит.

Хәлфинең үзен гөнаһсыз итеп, бар гаепне үги әнкәсе өстенә өяргә маташуын тыңлап торуы җирәнгеч иде. Әхмәтсафа, өздереп, кире уйламаслык итеп, соңгы сүзен әйтте:

— Бүген үк кит син! Авылны пычратып йөрмә моннан соң да. Син эшләгән кабахәтлекне иң соңгы адәм актыгы да эшләми.

— Кая китәргә? — Әхмәтсафаның болай усаллануыннан Хәлфи гел аптырашта калган иде.— Кая китим мин, ә?

— Һич тә булмаса, әнә кызылларга ияреп кит. Берәр җиргә барып чыгарсыз әле.

Әхмәтсафа сүзем бетте дигәндәй борылды да лапастан чыгып китте. Ишегалды яп-якты, дөньяны кояш яндыра иде.

Хәлфетдин шул көннән авылдан юкка чыкты. Аның кая киткәнен беркем дә белмәде.

* * *

Бер ел буе Госманнан хат-хәбәр көтте Мостафа. Узган яз улының өзек-төтек әйтелгән сүзләреннән кызылларга язылып, яуга китәргә җыенуын белгәч, ата кешенең миен мең төрле уй, мең төрле сорау яндырып үткән иде. Каршы килеп нишли ала, хуплап-үсендереп тә тора алмый. Гомәр абзыйның гел кабатлый торган сүзе бар: «Әйбер затлырак булган саен аны югалту куркынычы да күбрәк була. Кеше дә шулай»,— ди торган иде ул. Менә хәзер җир тырмап еласаң да, Госманны кайтарып кертеп булмый өйгә. Жәл егет, жәл. Исән генә була күрсен. Кемнең кадерлесе булсын ул анда? Кызыллар да шул, чынны ялганга, ялганны чынга авыштырып кына йөриләр, ахры. Элек Рәсәйдә кешенең кадере юк иде, кызылларның да кеше кадерен белүләре шикле. Күп нәрсәнең беркайчан да кадере булмый. Рәсәйдә нәрсә күп? Кеше, әлбәттә! Иң кадерсезе дә кеше җаны, кеше гомере булачак, димәк. Кол тәхеткә менсә, ил ләхеткә керер, дигәннәр.

Бүген Каргалыга ниндидер гаскәриләр килүен күреп алгач, күңелендә яшерен өмет чаткысы сызылып үтте. Иртүк күңеле урыныннан купты. Сәбәпчесе — ап-ак чәчкәгә төренгән алмагачлар булса да, күрәсең, бу алгысынуның тагын бер хикмәте бардыр. Сәбәпсез җил дә исми, ди китап. Әллә нинди ятышсыз адымнар белән кайтып кергән хатыны Шәмсиягә артык игътибар итмәскә тырышты ул. Иртән яшь ара-

лаш: «Фәтхулла сугышка киткән елны да...» — диеп, үксиүкси ишегалдына чыгып китүен исенә төшереп, йөрәге күкрәк читлеген умырып атардай булып талпынып алган иде. Аның әле һаман урынына утырып бетә алганы юк.

Нинди гаскәр керде микән авылга? Кызыллар булуына иманы камил. Зур эшләр майтармакчылар бугай, соңгы араларда авылга еш киләләр, халыкны җыеп, митинг ясап, яңа хөкүмәтнең ярлы-ябагайга бүләк итәчәк бәхетле көннәре турында гәп куерталар. Хәлле кешеләргә ни-нәрсә күрсәтер микән бу хөкүмәт? Тәхетне ныклап үз кулларында тота башлагач күренер инде анысы. Бик тә тәхеткә хуҗа булып аласы килгән кемсә хакында кемдер әйткән: тәхетне төлке кебек әләктереп алды, тәхеттә бүре сыман кыланды, ахыр чиктә, эт үлеме белән үлде, дигән. Бәлшәвикләр шулайрак кыланалар менә.

Мостафа, үткән ел, Госман белән аерылышкан мәлдә, гел бер сүзне тәкрарлады:

— Ашыкмыйсыңмы, улым, ашыкмыйсыңмы?

Госман, башын түбән иеп, салынып төшкән кулларын кая куярга белми, әле кушырып, әле сәер генә угалаштырып, бу адымны үзенчә нигезләп азапланган иде:

— Булмый болай, әткәй. Яшәү түгел, җәһәннәмгә әйләнде тормыш. Качкын хәлен аңлый торгансыңдыр, яхшылыкка алып бармый икән. Башта да җүнле уй юк. Хәл итәргә кирәк...

Мостафа, улының яшь тибеп чыккан күзләренә карап, тирән сулыш алды да, фатыйхасын бирде:

— Хәерле булсын. Бер син генә түгел инде, балакай. Аллаһ ташламасын, шул гына...

...Авыр сөйрәлеп Әхмәтсафа кайтып керде. Нигәдер күлмәген кулына урап тоткан. Аның мондый төшенке кыяфәттә кайтуын Мостафа артык арганнан күрде, ял итсен, хәл алсын дип борчымаска булды. Әхмәтсафа авылга кызыллар килүен, араларында үткән ел Госман абыйсын гаскәргә яздырып алып киткән Усманов дигән комиссарның да булуын хәбәр итте. Моны ишеткәч, Мостафа каударланып чыгып китте. Шәмсия, берни булмагандай, Әхмәтсафаны чәйләп алырга чакырды. Үсмер күзенең агы белән үги әнкәсенә карап алды да әткәсе артыннан чыгып йөгерде.

Әткәсе кай арада Яңа мәчет янына килеп җиткән диген: Усмановны эзләп тапкан, моңарчы эчен тырмап торган сорауларын да бирергә өлгергән икән. Усманов әткәсен тынычландырырга тырыша. Үткән ел хәлләр шәптән булмаган икән, Каргалы егетләре, аннан тормаган сәбәпләр аркасында, төрле фронтларга озатылганнар. Госманны яхшы хәтерли комиссар.

— Кирәк чакта ипле, кирәк чакта тәвәккәл иде улыгыз. Акыллы егет, тиз генә юкка чыкмас. Хәбәре килер, сабыр ит инде, абзый, — диде ул, гаепле сыман, күзен аска төбәп.

Гаеп дип әйтерлеге шул: ул Оренбурдан киткәч, Мәскәүгә барып татар-мөселман укчы бригадасы төзү артыннан йөргән иде, шул чагында күп егетләрне Көньяк фронтка озатып өлгергәннәр. Госман да шунда эләккән булырга тиеш. Инде бригада төзелеп бетеп килә икән. Үткән елдагы кебек, егетләрне өстенә солдат киеме кигән уңайга, кулына винтовка тоттырып, сумкасына бер уч патрон салып ут эченә кертеп җибәрү булмаячак, дип ышандыра комиссар бүген кызыл гаскәргә язылырга ниятләгән яшьләргә. Әхмәтсафа күзе белән Хәлфетдинне эзләде. Яшьләр арасында Хәлфи юк иде.

Үз теләге белән язылучыларны Усманов нигәдер: «Гаскәргә «күңелле» булып язылучылар», — диде. «Нинди «күңелле» булсын инде алар?» — дип, үз-үзенә сорау бирде Мостафа. Аптыраганнан язылa яшьләр, башны алып кая олагырга белмәгәннән. Әмма җанга ятышлы булганы шул: комиссар кат-кат әйтте, яшьләр сугыш һөнәренә өйрәнми торып, окопларга җибәрелмәячәк! Башта Самарага, аннан, бәлки, Казанга ук, әле төзелеп бетмәгән 1 нче татар-мөселман укчы бригадасы карамагына китәчәкләрен аңлатты. Комиссарның ипле сөйләшүенә егетләрнең янәшәсендә торган Мостафаның күңеле булды. Әйтерсең әлеге егетләр арасында аның Госманы да бар...

— Берүк, шулай, син сөйләгәнчә булсын инде, туган. Япь-яшь егетләрне мылтык та тота белмәгән килеш яуга җибәреп, аларны чебен урынына кырдырудан ни файда хөкүмәткә? — дип, аның сүзен җөпләп куйды. — Дошман дигәнең дә акылсыз түгел, кемнәр белән алышканын белеп керә яуга.

— Дөрес, абзый. Дошман белекле, зиһенле икән, безгә дә ахмак булу ярамый. Дошман көчле икән, без тагын да көчлерәк булырга тиешбез. Башы булган кеше дошманыннан күп акыл җыя ул.

Усманов, гади авыл агаеның шулай үзен җөпләп торуына кәефе килеп, кулын-кулга чалт итеп сугып куйды. Аның күзендә яшьлек очкыннары уйнаклап алды.

— Мин яшь совет властен яклап, байтак сугышларда катнаштым, — дип мөрәҗәгать итте ул егетләргә. — Сез әле тәвәккәлләргә генә җыенасыз. Дөрес эшлисез! Без, татар-мөселманнар, ахыр чиктә барыбыз да бергә, бер илдә — татар илендә яшәргә тиешбез. Бер генә кеше дә, бер генә халык та үз язмышын хәл итүне башкалар кулына тапшырырга тиеш түгел. Безгә үз дәүләтебез кирәк, гаскәрсез дәүләт юк! Безгә беркем дә гаскәр төзеп бирмәячәк. Мин моңа ышандым инде. Үзең корал тотып яклыйсың икән, дәүләт ун мәртәбә

кадерлерәк булыр. Бергә булыйк, туганнар! Татар-мөселман исеменә тап төшермик!

Усманов үз телмәреннән үзе хисләнеп китте. Аны тыңлап, яктырып басып торган Мостафаның кулын җәһәт кенә эләктереп алды һәм нык кына кысып куйды. Андагы дәрт, кайнарлык, үз-үзенә ышануны кул кысуыннан да чамаларга була иде.

— Тагын сәгать ярымнан безнең артистлар авыл халкына концерт куялар,— дип дәвам итте Усманов.— Менә сәхнәне генә әзерләп бетерсеннәр.— Ул Яңа мәчет каршындагы мәйданның каршы ягына төртеп күрсәтте. Анда гаскәриләр кайнаша, үзләренчә сәхнә ясап мәш киләләр иде. Чаршау элеп куйганнар, аның артында кемнәрдер кайнаша. Әхмәтсафаның күңелен кыбырсытып куйганы шул, чаршау артыннан хәрби киемдәге ике кыз чыгып, шул тирәгә җыелган бала-чагалар янына килеп, нидер сорашкан булып кыландылар. Бүгенге концерт өчен нидер кирәк иде, ахры. Яшь кызларның чытлыкланып кына йөрүләре булдымы бу — Әхмәтсафага караңгы, әмма зифа гәүдәләренә искиткеч ятышлы иде солдат киеме. Кызларның да гаскәриләр белән йөрүләреннән таң калган күңелен иләс уйлар җилкендерде. Яше җитсә, бүген үк кызылларга язылып гаскәргә китәргә әзер иде ул. Ярый әле Хәлфи күренми, аңа харам мондый кызлар белән бер сафта йөрү. Үзе дә сизми калды, кай арада әткәсе янәшәсенә килеп баскандыр.

Усманов, Әхмәтсафаны күреп алгач, аның иңсәсенә кулын салып, шаяртып куйды:

— Мин бу егетне беләм бит! Үткән ел Хәйбри отряды эләктереп алган егетләрне үлемнән йолып калган иде.— Усманов, авыр сулап, каядыр, дала якларына карап, сагышланып өстәп куйды: — Хәйбри юк инде. Сезнең авылдан туры далага, дутовчыларга каршы чыгып китте үз отряды белән. Сабыр итәргә, өстәмә көчләр килгәнне көтәргә кушкан идек, тыңламады. Партизанлык көчле иде шул анда, шул очрашу соңгысы булды... Дутовчылар белән беренче бәрелештә үк казаклар тураклап бетергән үзләрен. Каргалы егетләренең бәхете булгандыр, шушы егет килеп җитеп, хәбәр салмаган булса...

Әхмәтсафа комиссарның сүзләреннән тетрәнеп китте:

— Каргалыдан да егетләр кушылган иде бит аңа,— диде ул ачынып.— Госман абый да...— Ул артистларны күзәтеп йөреп, Усманов белән әткәсенең сөйләшкән сүзләрен ишетми калган иде.

— Алар исән-сау калдылар ул чакта,— диде Усманов, үсмерне тынычландырып.— Үзләрен Хәйбригә бирмәдем. Яшермим, тарткалашып караган иде. Егетләрне Казанга исәнимин илтеп җиткергән идем лә...

...Каян килеп чыккандыр, Әхмәтсафаның тезләренә Бибиҗамал килеп сарылды.

— Китмә, абыкай, җибәрмим,— дип, үзенчә такылдады дүрт яшьлек кызчык.— Китсәң, мин дә елыйм, инәй дә елый...— Ул узган ел Госман абыйсын озатып калуын онытмаган икән, бүген Әхмәтсафа абыйсы гаскәргә китә дип үрсәләнә иде.

Әхмәтсафа, күлмәк итәге белән сеңлесенең борын тирәсен җыештырып алды да, Бибиҗамалны кулына күтәреп, әткәсенә карады:

— Кайтыйк инде, әткәй. Госман абыйны белгән-күргән кешеләр юк икән монда.

— Тамаша карарга килегез,— дип, Усманов артистлар ягына атлады.

...Әхмәтсафа Яңа мәчет янына килеп җиткәндә, концерт башланган иде инде. Матур тавышлы бер ир-егет, сүз дә юк, артисттыр, кайнарланып декламация сөйли:

... Җаек суы — яман су,  
Ага бик шәп һәм ярсу;  
Себереп түк дошманны,  
Җәй булмасын ямансу.  
Җаек суы бик тирән,  
Яз җыела кар суы.  
Дошман шунда себерелсә,  
Басылыр йөрәк ярсуы.

Шунсы кызык, бу шигырьне укыганы бар иде Әхмәтсафаның. Кызыллар калдырып киткән гәзиттән иде бугай. Авторын да белә — Галиәсгар Камал. Артистның шартка яраклаштырып, шигырьне укыганда «Идел» сүзе урынына «Җаек» дип алыштыруын да чамалады. Әхмәтсафаның хәтере шәп, шигырь «Актык йомрык» дип атала иде.

Сәхнә тирәсен яшьләр, бала-чага сарып алган, Әхмәтсафа аптырабрак тора иде, аның каршысына йөзенә шатлык хисләре йөгергән Усманов килеп басты.

— Нәрсә, егеткәем, урын да калмаганмы? — диде ул, шат тавыш белән.— Халык җыелырмы дигән шик бар иде күңелдә, шөкер, килгәннәр бит,— диде ул үсмергә, күптәнге танышы белән сөйләшкән кебек.— Шик күңелгә вәсвәсә сала бит ул. Вәсвәсәле күңелгә исә шайтан кереп оялый.— Ул шулай сөйләнә-сөйләнә Әхмәтсафаны кулыннан җитәкләп диярлек сәхнә алдына алып китте.— Сиңа гына урын табарбыз, ни дисәң дә син инде безгә булышлык күрсәтеп өлгергән егет.

Үсмер егет үзенә булган игътибардан кинәт кыюсызланып, комиссарның чакыруын кабул итмәгәндәй, читкәрәк каерды.

Усманов йөзендәге елмаюны сүрелтми, йомшак, тик боеручан тавыш белән Әхмәтсафаны туктатты:

— Нилектән болай халыктан шүрлисең? Онытмасаң, узган ел сине күтәреп алырдай кыланды Каргалы халкы. Синнән дә хөрмәтле кеше юк иде авылдашларың алдында.

Шунда гына Усманов үсмернең берүзе булмавын искәреп алды. Аның кулына асылынган Бибиҗамалны күреп, көләсе итте:

— Нинди чибәр кыз ияртеп йөрисең? — дип сорады ул, кызчыкның чибәрлегенә соклануын яшермичә.

— Сеңлем,— диде Әхмәтсафа, сүзне тизрәк түгәрәклисе килеп. Һаман да кешеләрнең игътибар үзәгендә булып тору уңайсыз иде аңа. Якын-тирәгә җыелган яше-карты көяз комиссарның шулай үз итеп Әхмәтсафа белән сөйләшүенә исләре китеп карап торалар иде.

— Кызыйның исеме ничек була? — дип, Усманов сөйкемле кызның бөдрәләнеп торган коңгырт чәчләреннән сыйпап алды.— Абыйсын ярата икән, кара әле аңа ничек тагылган.

— Бибиҗамал,— дип чатнатып әйтеп салды кызчык.

Абыйсы аны кулына алды.

— Бибкәй-кыз икә-ән,— диде Усманов сузып.— Мондый сөйкемле кызга килешә икән Бибкәй исеме,— дип кабатлады ул. Шушы көннән башлап, Бибиҗамал исеме онытылыр да, үзен Бибкәй дип кенә атап йөртә башлаячакларын кыз әле бөтенләй белми иде. Ул, яп-якты зәңгәр күзләрен зур итеп ачып, сабыйларга гына хас үтә ышанулы тавыш белән сузып кына сорау бирергә дә өлгерде:

— Абый, бүген кемнәрне үтерергә килдегез?

Усманов бер мәлгә югалып калды, шулай да үз-үзен кулга алып, елмайган кыяфәтен югалтмыйча, бармагын иреннәренә китерде:

— Тс-с-с,— дигән булды.— Без беркемгә дә тимибез, сеңлем. Дошманнарны гына куабыз. Кирәкми алар безгә, китсеннәр.

Кыз бер теле ачылгач, туктап калырга исәпләми иде инде. Бәләкәй бармагын сәхнә ягына төртеп, тәтелди бирде:

— Дошманнар әнә тегендә, шуларны куарга кирәк. Китсеннәр, иеме, абыкай?..

Абыйсы җавап биреп тормады. Үзенә баш кагып, кырт борылып киткән Усмановка нидер әйтмәкче иде, кире уйлады, алдагы урыннарның берсенә барып чүмәште. Бибкәй абыйсы алдында боргаланып утырды-утырды да, нәни йомшак кулын аның муенына салып, изрәп йоклап китте. Әхмәтсафа, бар дөньясын онытып, сәхнәгә төбәлде.

Ул арада сәхнәгә Усманов сикереп менде.

— Җәмәгать, — диде, сөйлисе сүзләренең бик тә мөһим булачагына басым ясагандай, уң кулын алга суза төшеп, бер мәлгә тын калды. — Җәмәгать, — дип кабатлады ул, үзе тудырган киеренкелекне йомшарта төшеп: — Менә насыйп булгач, тагын сезнең авылга килеп чыктык. Бу юлы инде мин сезнең каршыда регуляр Кызыл Армия вәкиле, Казанда оешкан 1 нче татар-мөселман укчы бригадасының иң әзерлекле, иң булдыклы, кыю сугышчылардан торган полкның комиссары буларак чыгыш ясыйм. Кызыл фронтта партизанлык чоры бетте. Дошманнарга каршы барган аяусыз яуда төп сүзне оешкан Кызыл Армия гаскәрләре әйтәчәк. Милли бригаданы оештырырга рөхсәтне совет хөкүмәтенең олы җитәкчеләреннән алдым. Ышанам, алар азатлык яуларында сынатмаслар. Әле май башында гына Казанга иптәш Калинин килгән иде. Безнең частьларны карап, безнең ни-нәрсәгә яраклы икәнлегебезгә бәя биреп китте. Татар-мөселман бригадасы Михаил Иванович Калининга ошады. Кем белми, әйтеп китим, ул Мәскәүдә, Кремльдә Ленин белән янәшә эшләүче большевик. Яшереп тормыйм, Мәскәүдә дә төрле түрә бар, әмма Калининга ышанырга була. Эшче арасыннан күтәрелгән кеше. Менә аның киңәше белән безне Оренбур ягына, колчакчыларга каршы сугышырга җибәрделәр...

Халык шаулашып алды. Усманов аларның тынычланганын сабыр гына көтеп торды. Инде сүзне Каргалы халкы үз күзләре күргән, башларыннан кичкән вакыйгаларга борды.

— Күреп торасыз, дошман мәкерле һәм яхшы коралланган булуга карамастан, Кызыл Армия ныклы адымнар белән алга бара. Дутов казаклары сезнең канга да аз тоз салмагандыр...

Арадан берсе ачык итеп әйтеп ташлады:

— Безнең канга кызыллар күбрәк тә тоз салды әле.

— Булгандыр, сугыш чоры, кемнең кем икәнлеген сорап торыш юк. Мин фактларны гына китерәм. Дутовны кызыл гаскәр сугышчылары яңадан мәңге Оренбур далаларына аяк басмаслык итеп, арт сабагын укытып җибәрделәр.

Халык тагын шаулашып алды. Чөнки Дутов гаскәрләре арасында Каргалы егетләре аз түгел һәм мондагы кайбер кешеләргә Усмановның авызыннан чыккан әлеге сүзләрне тыңлап тору җиңел түгел иде. Моны оратор үзе дә сизеп алып, уң кулын тагын кисәк алга сузып җибәрде. Әхмәтсафа беренче күргәндәй комиссарның кыяфәтенә күз салды. Һәрвакыттагыча, коңгырт бөдрә чәчләре кызыл йолдызлы фуражкасы астыннан килешле генә чыгып торалар. Өстенә кигән хәрби киеме уртачадан югары буена шулкадәр килешә, халык аның сүзләренә караганда, сөйкемле сөягенә карап кына тына төште, ахры.

— Тагын да ары китсәк, Вәлиди төзегән башкорт гаскәрләре совет хөкүмәте ягына чыкты. Хәзер бергәләп акларга каршы сугыш алып барабыз. Башкортларның үзләренең хөкүмәтләре бар, безнең татарларның да аерым дәүләте, үз гаскәре булыр. 1 нче татар-мөселман укчы бригадасы төзелү моңа ачык дәлил. Дөньяда барган хәлләрдән артта сөйрәлергә тиеш түгел татар халкы,— дип дәвам итте Усманов. Аның карашы Әхмәтсафа алдында изрәп йоклап киткән сабый — Бибкәйгә төртелеп, туктап калды. Бертын сүзсез торгач, бүген генә кызыл гаскәрләргә язылган егетләрне күздән кичерде.— Менә бүген берничә егетегез кызыл гаскәргә «күңелле» булып язылып китә...

— Ихтыяри-мәҗбүри,— дип төзәтергә өлгерде кемдер.

Аны да төзәтүче табылды:

— Теләк белән,— диде кемдер.

Кемдер хихылдап көлеп куйды.

— Уен түгел, җәмәгать. Әйе, бүген хатын-кызлар кол хәлендә. Алар хәтта тормыш корып җибәрү, белем алу мәсьәләләрендә дә искелектә хөкем сөргән гаделсез кануннарның корбаны булып яши бирәләр. Ә бит алар да үз язмышларына үзләре хуҗа булырга хокуклы. Хәтта нәни Бибкәй дә бүгеннән үзен кеше итеп тоярга тиеш. Үсеп җиткәч, үзе теләгән гаилә тормышы корсын ул. Мәхәббәт иреге булырга тиеш түгелмени, ә? Бүгенге көннең төп шигарьләре: «Хатынкызга ирек!», «Бетсен коллык, бетсен хурлык!» икәнлеген инде күпләр аңлыйлар. Менә шуның бер мисалын күрсәтәсебез килә. Бүген Каргалыга беренче сәхнә карлыгачларыбыз — биюче кызлар Мөкәррәмә Әсфәндиярова, Камилә Мәҗитова иптәшләрне алып килдек. Бу уналты яшьлек кызлар, коллык пәрдәсен ертып ташлап, кадими туганнарының каршы төшүләренә, һичнинди ай-вайларына карамый кызыл гаскәрләргә мәдәният хезмәте күрсәтүчеләр сафына кушылдылар. Өйдә, дүрт стена арасында якты дөньяны күрергә мәхрүм кызлар, хатыннар шулай ук үз ирекләре өчен көрәшә башласыннар, тигез хокук дауласыннар. Милләтнең Жанна д`Арклары, Софья Ковалевскаялары, Мария Ермоловалары булсын! Безнең милләт башка халыклардан ким түгел.

— Хатын-кызга ирек бирсәң, ишәрсең ишәк чумарын,— диде берәү, ачулы тавыш белән.— Әле болай да кулдан ычкынырга тора алар, иблис токымнары. Коткы салуы гына ансат...

Әлеге сүзләрдән агайлар янә бер шаулашып алдылар, тик бу шау-шу нигәдер күңелле төс алган сыман тоелды.

— Иптәш Еникеев, концертны дәвам итегез,— диде Усманов һәм, сәхнәдән төшеп, Әхмәтсафа янындагы буш бүкәнгә килеп утырды.

Комиссарның үз-үзен тотышы да, сөйләү куәсе дә Әхмәт-

сафага бик ошый иде. Баягы хисләр янә уянды: үзенең дә җиңү артыннан җиңү яулап баручы кызыл гаскәрләр сафына басып, яудан бушаган чакта шулай концертлар карап, солдат гомере үткәрәсе килә башлады.

Ул арада күңелләрне җилкетеп скрипка, мандолина авазлары ишетелде, мәйдан өстендә дәртле бию көе яңгырый башлады. Көй башламы уйналып бетәр-бетмәс, сәхнәгә милли киемнәрдән ике кыз атылып килеп чыктылар һәм җитез, җиңел хәрәкәтләр белән биеп тә киттеләр. Тамашачылар арасында кызларның бу гамәлләрен хупламаучы сүзләр ишетелгәләп алды:

— Бәндәдән курыкмасалар, Ходайдан курыксыннарые, бәдбәхетләр, ни кылананалар бит, ә? Дөньялар ничек үзгәрде...— диде бер агай.

— Кызлар гына түгел, бичәләр азына башлады. Барып чыктык инде, туганнар...

— Әйтмә дә генә инде. Бөтен халык алдында арт сикертеп йөргәннәрен күрсәләр, ата-аналары нишләрләрие микән бу иблисләрнең? Таралышыйк, җәмәгать, яшьләрнең азынганы гына җитмәгән, боларны карап утырып, үзебез дә гөнаһлы булабыз!

Шулай да мыңгыр-мыңгыр килеп утыручылар аз иде. Арада кызларның биеп йөрүләрен килештермәүчеләр булса да, авыл агайлары һич кенә дә концертны ташлап кайтып китәргә ашыкмадылар. Ул гына да түгел, аерым бер ләззәт һәм канәгатьләнү белән сылу кызларның сәхнәне ду итеп, табан асларыннан ут чыгарып биюләрен тамаша кылып утыра бирделәр. Гүзәллек каршында акылы булган кеше гөнаһ уйлар уйлап утыра димени...

Кызларга карап әсәрләнгән Усманов, берзаман әллә онытылып китеп (һәрхәлдә, тамаша кылучылар шулай кабул иттеләр), әллә шулай алдан сөйләшеп куелганмы, урыныннан кубып, сикереп кенә сәхнәгә менде, күз ачып йомганчы, сәхнә уртасына килеп басты, көй уңаена гәүдә-иңсәләрен ятышлы гына уйнатып торды да, кызларга кушылып, килешле хәрәкәтләр белән биеп тә җибәрде.

— Ике титигә бер әтәч, әйттерә генә,— дип хихылдап алды бер абзый.

— Әтәчләре бер кетәк, титиләре генә аз икән шул,— диде аңа каршы икенчесе.

— Шаярма,— дип сүзгә кушылды өченче агай, белдекле тавыш белән.— Әллә син ул титиләр теләсә кайсы йолкыш әтәчкә әләгә дип белдеңме? Түрәләрдән артмыйлар алар. Япун сугышында күрдек инде, кызлар барые, шәфкать туташлары диләрме, түрәләрдән узып бер солдатка да тәтемәде алар. Түрәләр рәхәтләнде инде...

...Концерт беткәч, артистлар җиһазларын олауга төяргә керештеләр. Әхмәтсафа концертта алган тәэсирләрдән айнып бетә алмыйча, бер читтә басып тора. Усманов инде ат өстендә икән, отрядына кычкырып фәрман бирде:

— Барыгыз да атларга! Гаскәргә яңа язылучылар олауга утырып барасыз, кузгалдык! Алга!

Солдатлар, атларга атланып, сафка бастылар. Олаулар да әзер икән, кузгалышып китә башладылар. Тонык шыгырдаган тәгәрмәч тавышыннан җан өшегән сыман булды. Ни өчен шулай икәнен Әхмәтсафа аңлый да, аңлата да алмас иде. Ул, керфекләренә яшь эленгәнен тоеп, олауга төялгән авылдашларына җайсыз гына кулын изәде. Госман абыйсы исенә төшеп, күңеле җебеп алган иде булса кирәк.

Усманов концертның уңышлы үтүенә сөенеп бетә алмый иде. Тагын берничә көннән аның полкы дошманга каршы яуга куылып кертеләсен дә, каршы килүенә карамастан, полкны иң авыр участокка куеп, бернинди яклаучысыз калдырачакларын да, беренче бәрелешләрдә үк казаклар тарафыннан тар-мар китереләчәкләрен дә белми иде. Каргалыдагы концерт полкның тәүге һәм соңгы җиңү булачагы башына да килми, ул, үзен бу мизгелдә бөркеттәй хис итеп, Оренбурга кайтып бара иде.

...Көне буе авызына бер валчык ипи капмаса да, нигәдер ашыйсы килмәде Әхмәтсафаның. Ул кече өйгә кереп сәкегә капланды, авырлык белән генә кабат күтәрелеп, баш астына кечкенә мендәр ташлады да күзен йомды. Бүген булып узган хәлләр бер-бер артлы башыннан кичеп, аның талчыккан җанын тагын да газаплыйлар, яңа әрнүләр генә өстиләр иде.

Шулай күпме яткандыр, урам якта гадәти булмаган тавышлар ишетеп, күзләрен ачты. Өй эченә караңгылык иңеп килә икән, димәк, Әхмәтсафа йокымсырап киткән. Сагаеп, мендәрдән башын күтәреп тыңлана башлаган иде, атылып, өйгә әткәсе килеп керде.

— Кем бар өйдә, торыгыз! Янабыз, пужар! Каргалы очына ут капкан, әйбер-караны чыгарып өлгерик,— дип, әллә нинди ят, калтыравык тавыш белән кычкыра-шаулый, ничек тиз килеп керсә, шулай ук җәһәт кенә чыгып та китте.

Әхмәтсафа, абына-сөртенә, урамга атылды. Һаваны тутырып: «Янгын, пожар»,— дигән авазлар яңгыраса да, урамда кешеләр аз күренә, чөнки һәркем үз ихатасында чабыша. Каргалы халкының янгын мәсьәләсендә тәҗрибәсе җитәрлек, авылда янгын чыкмый тормый. Мондый җилле көнне камыш түбәле саман йортлардан торган урамны ярты сәгать эчендә ут ялмап кына алачак. Шуңа күрә һәркем үз йортын коткарып калырга тырыша. Инде өйне саклап калып бул-

мый икән, дөнья көткәндә җыйган әйбер-карасын, булган малын ут авызына калдырмаска омтылырга кирәк бит.

Ут чыккан йорт үзләреннән ерак түгел иде. Кыш буе Мифтах хәлфәдә бергә укыган сабакташы Кәримнәр йорты давыллап яна. Ут беркемне дә аяп тормый, инде алар йортыннан күрше-куләнгә җәелә. Һаваны торган саен төтен болыты каплый. Җил янган камыш учмаларын дулата-дулата авыл буйлап тарата, Әхмәтсафаларның йорты януы да котылгысыз иде. Әтисенең ачыргаланып кычкыруы шушы куркынычны сизүеннән иде дә инде.

Үзенә таба җан-фәрман чабып килүче Саттар белән Әбдерәшитне күреп, Әхмәтсафа дус малайларның каршысына төште. Белә, беркемнең дә сөйләшеп торырга вакыты юк, шулай да кызыксынуны җиңеп булмый. Саттар белән Гаптери аның яшьтәшләре, сабакташлары. Әхмәтсафаны күргәч, үзләре дә бер тынга тукталасы иделәр.

— Кәримнәр яна, малай,— диде Саттар, яшенә карагандa җитди сөйләшә торган үсмер.— Солдатлар торганые алар өендә, шулардан тәмәке урлап калган. Бүген, ничектер җай табып, өй артларында, алабута арасында тәмәке тартырга маташа икән, әнкәсе килеп чыккан өстенә. Кәрим куркудан тәмәке кабызырга сызган шырпысын өскә чөеп җибәргән. Бәхетсезлеккә, янган шырпы түбә камышына килеп төшкән. Әнкәсе аңыша алмый торганчы, түбәгә ут үрләп тә киткән. «Күз ачып йомганчы төреп кенә алды ут»,— дип елый Бәдәр апа.

Әхмәтсафа Саттарның сүзен тыңлап бетерә алмады, өйдән әткәсенең ачулы тавышы ишетелде:

— Әхмәтсафа, дим, кая олактың? Әйберләрне чыгара башла кече өйдән! Кечкентәйләрне Тайфә карчыкка җибәр, ут алар ягына бармый. Өске урамнан урап үтсеннәр. Тиз бул, әй, малай актыгы!

Ул ихатага йөгереп кергәндә, әтисенең дә, үги инәйнең дә күзенә ак-кара күренми. Ишегалды уртасына әйбер-кара чыгарып өелгән. Әгәр ут килеп җитсә, бу йорт кирәк-яракларының исән калуы икеле, ә ат җигеп, әйберне арбага төяп илтеп булмый: быел яз башында ук колчакчылар Мостафаның сәүдәгә йөри торган ике шәп юртагын алып чыгып киткәннәр иде. Атлыдан атсыз калганнар иде, хәзер йортлыдан йортсыз итмәкче була язмыш аларны...

Әхмәтсафаның сизенүе дөрескә чыкты. Янгыннан алар бик аз гына әйбер-караны саклап кала алдылар. Ут кемнең кем икәнен тикшереп тормый, каралты-кураны рәттән ялмап килеп, аларның йорт-җирләрен дә көлгә, күмергә әйләндерде дә куйды.

Уйлау сәләтеннән мәхрүм калган Мостафа агай, гаҗиз

калып, кара күмергә әйләнгән алмагач кәүсәләренә карап, гел бер үк сүзләрне кабатлады:

— Һай, алмагачлары, һай, шау чәчкә генә ие бит... Әле иртән генә ап-ак иделәр. Язмаган икән, язмаган икән балакайларымны алма белән сыйларга... — Һаман төтенләп утырган йорт нигезеннән урый да тагын бакчага үтә, тагын шул ук сүзләрне кабатлый иде: — Һай, алмагачларым, һай, шау чәчкә генә ие бит...

...Икенче көнне Мостафа агай кемнәндер арык кына ат алып торып, янгыннан ни хикмәт белән исән калган арбага уттан саклап калырга өлгергән әйберләрен төяп, Тайфә карчыкның курчак өедәй кечкенә йортына күченделәр.

## VI

...Янгыннан соң бер ел үтеп тә китте. Шушы ел эчендә йорт төзеп керербез дигән хыял да тормышка ашмый калды. Янгыннан соң ук Мостафа агай авырып китте. Яңа гына тернәкләнеп килә. Әткәсе Әхмәтсафаны ничек кенә булса да укытырга омтыла. Авыру кешеләрнең күпчелегенә хас булганча, башында чабышкан уйларын тизрәк тышка чыгарып түгәргә ашыга әткәсе. Улына акыл биреп калырга ашыккан кебек тә тоела иде.

— Бәхетне аны күп эзләдем, улым,— диде ул, беркөнне Әхмәтсафаны үз янына чакырып китереп.— Кеше күпме генә казганса да, үзе теләгәнчә бәхетле була алмый икән. Шунысы да бар — без үзебез уйлаганча бәхетсез дә түгел. Урталыкта яши адәм баласы. Ике нәрсәгә туры карап булмый икән, кояшка һәм үлемгә. Тере килеш мәет булып яшәүдән Ходай сакласын. Укырга кирәк сиңа, улым. Гомәрхан абыең эшкә дәрт иде, исән-имин кайтса, ул югалмас. Госман укымышлы егет, затлы егет иде. Югалтудан куркам аны... Нәселне вакламаска кирәк, улым, Дәүләтъяр нәселен балкытып торган йолдыз бул син. Укуың әйбәт булды, уңны-сулны аера beләсең. Кемгә ияргә, кемнән качарга кирәклеген дә чамалыйсыңдыр. Денсез чукына, уйсыз үкенә. Башыңны күтәреп йөр, шул чагында гына күренә күктәге йолдызлар. Йолдызга карарга өйрәнмәгән кеше төнлә дөрес юл таба алмаячак. Ходай биргән зиһенең, укып җыйган белемең чиген үтеп, белексезлек ягына чыкма. Шундый заман килде, хәзер комсызлар, әрсезләр өскә чыга. Комсызлык берәүләрнең зиһенен томалый, берәүләрнең күзен ача — болганчык суда ни-нәрсә эләктереп калырга мөмкин икәнлеген белеп алганнар алар. Башка адәмнәрнең акылын күреп, шул акылны да үзеңә ала алсаң, яшәүләре күпкә җиңел булыр... Укырга теләгең, дәртең бар, укы син, улым,— дип, сүзен тө-

гәлләгән иде әткәсе ул чакта. Шушы сөйләшүдән соң әткәсе аңа башка иркенләп акыл биреп утырмады. Әйтәсен әйттем, калганын үзе чамалар, дигәндер инде. Бу сөйләшүнең ахыры шул булды — Әхмәтсафа Оренбурда мөгаллимлеккә укырга дигән ныклы карарга килде.

...Ул төнне Әхмәтсафаның күзенә йокы кермәде. Керфекләренә йокы эленеп, инде онытылып китәм дигәндә, баш миендә янә уйлар өермәсе кузгала. Аңа быел җәй унбиш яшь тулды. Хәзер ул егет инде. Иртә таңнан диярлек торып, Оренбур каласына, «Хөсәения» мәдрәсәсенә укырга чыгып китәчәк ул. Яңа хөкүмәт мәдрәсәне укытучы-мөгаллимнәр хәзерли торган уку йорты итеп үзгәртте. Төнне черем итми үткәрүгә пошына да башлады. Гомеренең шундый җаваплы көнен талчыккан, алҗыган кыяфәттә каршы аласы килми. Күз алдына үзе кебек үк сабакка китәчәк Саттар, Хәмит, Пәрваз, Кәримнәр килә. Алар да шулай йокыга китә алмый урыннарында борлыгып яталар микән? Әллә дөньяларын онытып, тәмле төшләр күрә-күрә, күкнең җиденче катындагы серле бәллүдә яткандай хис итеп, бер хәбәрсез тәгәрәшеп йокы бүсәләр микән? Әхмәтсафа мондый төндә иптәшләренең бу кадәр битараф хәлдә ята алуларына һич кенә дә ышана алмый, өстенә бөркәгән чикмәнен бер якка селтәп, урыныннан ук торып утырды.

Әхмәтсафа ике җәй рәттән Сакмар буйлап сал агызды. Башка эшләргә караганда төшемле эш санала ул. Салны Оренбурдагы агач эшкәртү заводына илтеп тапшырасың да шул ук көнне исәп-хисап ясала. Мостафа агай авырып киткәч, янгыннан соң тиз генә мантып булыр кебек тоелмый иде. Өй салу турында әлегә уйлыйсы да юк, тормышны рәткә кертергә кирәк иде. Шуңа күрә сөенә-сөенә эшләде ул. Сал агызу белән турыдан-туры җитәкчелек иткән подрядчик Гариф аны башта эшкә алырга да теләмәде. Янгыннан соң күпләр яңадан өй торгызырга ниятләп, эш юллап, авылдагы байлар, кәсепчеләр тирәсендә бөтерелеп алдылар, тик авыл өстеннән әллә ничә мәртәбә үткән афәт-сугыш гарасатлары унтугызынчы елның язында дулаган янгыннан һич кенә дә ким түгел иде. Авылның чын байлары, дөнья күргән хәлле сәүдәгәрләр акларга ияреп, әллә кайларга китеп югалдылар. Совет хөкүмәтенә яраклашып үз эшен оештырырга омтылучы кәсепчеләрнең, сәүдәгәрләрнең әле авылның һәр мохтаҗына ярдәм итәрлек көче дә, теләге дә юк. Чөнки борынгы сәүдәгәрләрнең мохтаҗларга хәйрия ярдәм күрсәтүе, зәкят бирүе аларның абруйларын бермә-бер күтәреп, сәүдә эшләренә дә уңай йогынты ясый иде. Аякка басып килгән яңа байларның игелекле эшләренә бәрәү дә игътибар итми. Шулай булгач, ник дип әле алар үз малларын

уңга-сулга таратырга тиеш ди?.. Сөйләшкәндә Гариф эшләгән өчен хезмәт хакына өйлек бүрәнә бирергә вәгъдә итте, бераз акчалата да түләргә булды. Әхмәтсафа буйга калку булмаса да, чырыш һәм эшкә үҗәт егет иде. Сал агызучыларга авыл халкы аеруча ихтирам белән карый, бу эш теләсә кемнең кулыннан килми: ашкынып аккан Сакмар буйлап әллә кайлардан сал куу, әйтсәң, әйтмәсәң дә уен түгел шул. Ул шулай егетлек бусагасыннан атлап керде. Ерактагы урманнарда кемнәрдер кыш буе кисеп, елга ярына чыгарып хәстәрләгән салларны, язгы су тына башлагач ук эшкә тотынып, исән-имин Оренбур агач заводы урнашкан сөзәк яр читендәге агач будкалар тирәсенә китереп җиткерә башладылар алар. Әле агачларны ярга чыгарып өю дә алар өстенә төшә.

Гариф — сугышлардан исән-имин кайтып, үз эшен оештыра башлаган, озын гәүдәле, сүздә дә, кыланмышларында да тупас һәм аяусыз адәм. Мостафа агайга беренче җәйдә үк унбиш бүрәнә бирергә булган иде. Вәгъдәсез булып чыкты: Әхмәтсафа ике җәй ал-ялсыз сал агызып йөрүенә карамастан, эш өчен тияр әҗерен бирмичә, һаман алдагы елга калдырып килә. Быел көзгә табан Әхмәтсафа түзмәде, Гариф белән бераз сүзгә килеп алды. Теге мыскыллы рәвештә:

— Сиңа төс түгел ул йорт салып керү, үләттән калган нәрсә,— дип битәрләп ташлады.— Саманнан кирпечләр әвәлә дә, өегез йорт. Юк бүрәнә, моннан соң ымсынып та йөрмә,— дип, ярга килеп төртелгән сал буйлап, як-якка чайкала-чайкала чабулап китте.

Башыннан аягына кадәр ләмгә батса да, җиңү алар ягында иде. Шуңа күрә Гарифның җикеренүенә артык әһәмият бирмәде. Гариф дулаганнан гына салны борып агым уртасына чыгарып булса икән.

Сакмарның җайсыз борылышында, елга уртасында гомер бакый шулай кукраеп утыручы ак ташка килеп бәрелеп, ярга килеп сыланды сал. Бәхетсезлеккә каршы, салның койрыгында Әхмәтсафа ничектер үзе генә калып, ишкәкне нәкъ вакытында кирәгенчә чумдырып-каерып ала алмый калды. Җитмәсә, аның чираты да түгел, сүз тыңлап, бер егетне алыштырып кына баскан иде ишкәккә. Суеласы көнен белсә, әтәч таңны уятмас иде, ди әткәсе. Шул тыңлаучанлыгы аркасында ишетте дә инде яман сүзне Гарифтан. Әткәсе дөрес әйтә, юк дип әйтә белми ул. Теге егетнең дә әллә ни йомышы булмаган, тәмәке көйрәтеп аласы килгән. Бу урында ишкәккә һәрвакыт ике кеше баса иделәр. Зариф абзый: «Килеп җитә алмый калдым»,— дип аклана әнә... Агачлар начар беркетелгән булып чыкты. Бер араның бавы түзмичә шартлап өзелде, сал тарала башлады һәм агачлар котырып аккан

Сакмар иркендә, бер-берсе белән ярыша-ярыша Җаекка табан юл алдылар. Җаекка җитсәләр, аларны тотып алырмын димә инде. Әхмәтсафа, башкалар искә килеп өлгергәнче, салкын суга ташланды, кулында кай арада эләктереп өлгергәндер, озын саплы авыр багор, шул багор белән бүрәнәләрне яр читенә этеп чыгара, исәбе — ничек тә агачларны бер-берсенә каршы төшереп, аларның үз иркендә агуына комачаулык итүе иде. Һәр салда өч-дүрт егет була, Әхмәтсафалар салында Гариф белән дүрт кеше иде. Эшнең хәтәр икәнен башкалар да тиз аңлап алдылар, Әхмәтсафаның җан-фәрман агым белән көрәшеп матавыклануы аларга көч өстәде бугай, сәгать ярым азаплангач, агачларны тын култыкка җыйнап, салның исән өлешенә япсартып бәйләп, ныгытып куйдылар. Шулай да берничә агач, агым иркенә буйсынып, түбәнгә таба — Җаекка төшеп китте.

Эш тәмамлангач, шушы агачлар өчен Әхмәтсафага бәйләнде Гариф. Бу хәлгә таруда салчы егетләрнең һәммәсенең нинди дә булса гаебе бар, алар дәшми торуны хуп күрделәр. Зариф салчылар арасында иң өлкәне һәм тәҗрибәлесе, Әхмәтсафаны яклап авыз ачкан иде, Гариф аның да гаебен яхшы белгәнгә, ачу белән аңа бер генә карап алды, Зариф шым булды. Подрядчы исә торган саен котырды, Әхмәтсафаның якасына килеп ябышты:

— Атың коргыры, йоклап бардыңмы әллә? — дип, йодрыгын егетнең борын төбендә уйнатты.

Әхмәтсафа арыган, яңагы суырылып эчкә кергән. Өстеннән шыбырдап су ага, Гарифка каршы әйтү теләге бөтенләй юк иде.

Гариф аның саен котырды:

— Синдәй җебегәнне шушы эшкә алган мин җүләр. Малай-шалай эшеме инде сал агызу, йә? — Бу юлы ул Зарифка эндәшкән булды.— Әйт, Зариф, суга ташларгамы бу җүнсез малайны?! Күпме агачны Җаекка агызып юкка чыгарды бит, ә? — Ул ачынган тавыш белән тагын бер-ике кәлимә сүз өстәде дә Әхмәтсафаны сал өстенә аркылы-торкылы ташланган агач өеменә этеп җибәрде. Егет хаксызга рәнҗетелүдән болай да коелып төшкән иде. Каршылык күрсәтмәүнең әҗере шул булды, аягы каядыр эләгеп, «эһ» итәргә өлгермәде, бүрәнә аша очып, Сакмарның ләмле су читенә барып төште.

Моңарчы гаепле төстә торган Зариф түзмәде, йөгереп диярлек Гариф янына килеп басты:

— Тиясе булма! — диде ул, янаулы тавыш белән.— Әгәр ул булмаса, ярты сал агып бетәрие, ярый ул каушап калмады... Күрерием агачларны, Әхмәтсафа булмаса!

Менә шушы вакыйганың үчен алдымы, әллә шундый җай

гына көтеп йөргәнме, Мостафа агайның кат-кат өенә барып йөрүенә карамастан, Әхмәтсафа белән исәп-хисапны тулысынча өзмәде Гариф. Тукран кебек һаман бер сүзне кабатлады:

— Алдагы елда күз күрер, алдагы елда карарбыз...

Эшләп-эшләп тә җүнле сүз ишетмәгәч, Әхмәтсафа, Гариф сыман кеше хезмәте кулланып, әрсезләнеп, алдау-йолдау юлы белән баеп калырга омтылучыларга ялынып йөрмәскә кирәклегенә инанды. Андыйларны кўралмый башлавын да тоя иде. Шушы инану аның киләчәк юлын билгеләде дә инде. Ярый, теге чакта Зариф абзыйсы ярдәмгә килгәч, Гариф чигенде. Тик барыбер үз этлеген эшләде — тиешле хезмәт хакын түләмәде. Йодрык уйнатып Гарифны да, аның кебек кеше канын эчәргә омтылган яңа сәвит байларын да җиңеп булмаячак. Беләктә көч бар анысы. Шушы ике җәйдә җилкәләре тагын да киңәеп, җиргә нык басып йөрүче егеткә әйләнсә дә, аның да, аның сыман яшьтән эштә ватылган башка үсмерләрнең дә хаклык өчен көрәшкә чыгарга хәлләреннән килми иде. Бер генә юл кала — белем алырга, ярлыябагай яшьләргә берләшергә кирәк. «Беләге юан — берне егар, белеме булган — меңне егар»,— ди иде Мифтах мөгаллим. Әхмәтсафа еш кына комиссар Усмановны искә ала. Ул әйткән: «Бергәлектә — көч»,— дигән шигарьне иптәшләренә кабатлый. Авылда яшьләр берлеге төзеп мәш килделәр. Әхмәтсафа монда да башлап йөрүчеләрдән иде.

— Берләшергә кирәк. Яңа тормыш корабыз дип тотынганбыз икән, беренче эш шул булырга тиеш,— дип чыгыш ясады ул ялкынланып.— Каргалы халкын читтән берәү дә килеп якты тормышка чыгармас. Сәвит байлары да баш өстебезгә кояш яндырмас. Әүвәл яшьләр бер йодрыкка берләшергә тиеш.— Яшьтәшләре аның оста сөйләвенә биһуш китеп утыралар. Ә ул сөйли дә сөйли.— Шунсыз алга барып булмый. Салның таралганын күргәнем бар. Искә килгәнче, агачларны агым бөтереп кенә алды. Җаек суына килеп әләксәләр, бетте диген, тиз арада җилле-давыллы диңгезгә агып төшәчәкләр. Дулкын иркендәге аерым-аерым бүрәнәләрнең алдагы язмышын Ходай үзе генә белә...

Мифтах мөгаллимдә дүрт ел дәвамында хисап, җәгърафия, әдәбият, урыс теле укып белем алган егет, әтисенең киңәшен тотып, хәлфәсенең фатихасын алып, җәй урталарында ук «Хөсәения»гә документларын илтеп кайткан иде. Аңа авылдаш егетләрдән берничәсе иярде. Укырга керү дигәч тә, җиңел генә түгел икән: шартын китереп имтихан да алдылар хәтта. Белемнәренә карап кемне хәзерлек сыйныфларына, кемне башлангычның кайсыдыр баскычына укырга алдылар. Әхмәтсафа, бераз урысчасы сынату сәбәпле, хәзерлек сыйныфының икенче баскычына кабул ителде. Һәрнәрсәгә

үткер Саттар Ишбулдинның башлангыч сыйныфка кабул ителүенә барысы да көнләшкән кебек булдылар.

Аларны Әхмәтсафа тиз суытты:

— Саттарның ничек тырышып укуын барыбыз да беләбез. Көнләшеп торасы юк, шушы бер ел эчендә ике еллык сыйныф белемен үзләштереп, Саттар дусны куып җитү бурычы тора безнең алда. Мин үзем бу бурычны үтәячәкмен. Шундый заман — бер ел хәл итә кеше язмышын. Ашыгырга кирәк безгә, егетләр, ашыгырга. Өлгерми калсак, кемгә үпкәләрбез?

Моңарчы читтәрәк торган Пәрваз, иреннәрен бөрештереп, каршы төшеп маташты:

— Кая куасың безне, Әхмәтсафа? Боерган булса, укырга да өлгерербез, яшәргә дә.

...Әхмәтсафа тиз генә йоклап китә алмады. Күз алдына кара бәрхет түбәтәй кигән, чандыр гәүдәле, һәрвакыт ачык йөзле Мифтах хәлфә килеп басты. Аннан сабак алулары җан рәхәте иде.

Уку дигәннән, Әхмәтсафа, Каргалыда Мифтах хәлфә җәдитчә мәктәп ачып, балаларга сабак бирә башлаганчы да, өч-дүрт ел Вәлкәй хаҗидан сабак алып йөргән иде. Сабак дисәң, хәтерең калыр, Вәлкәй хаҗи биргән сабак-дәресләрдән Әхмәтсафа нигәдер ләззәт тапмады. Мәчет каршындагы мәдрәсәгә килеп керүгә, борынга тынчу ис килеп бәрелә. «Һәфтияк»ләрне ачып, өйгә бирелгән дәресләрне хәлфәгә әйтә башларга өлгермисең, ул, сабакны өзеп, эшен өлкән шәкертләргә тапшыра да, үзе йә берәр сәүдәгәргә аш мәҗлесенә, йә җеназага-фәләнгә дип чыгып китә. Авыл зур, унбер мәчет булса да, муллаларга, хәлфәләргә эш табылып кына тора. Аларның мәҗлес эше нәрсәләрнең берсеннән дә каласы килми. Хәлфә чыгып китүгә, мәдрәсәдә дәрес бирүнең ысулы үзгәрә. Өлкән шәкерткә тагын биш-алты «ярдәмче» куштан табыла. Юк кына сәбәп табып, кечерәк шәкертләрнең аркаларына чыбык белән «шелек» сугып, күңелләрен басалар. Китә елашу, китә ызгыш — чыда гына.

Шундый бер «шелек» сугу вакытында, Әхмәтсафа дусты Габдерахман белән, малайлар аны Әптери дип кенә йөртәләр иде, букчаларын алып, мәдрәсәдән чыгып тайдылар.

Яз көне иде. Якты көнгә килеп чыккач, малайлар үзләрен шук-кыбырсык кәҗә бәтиедәй хис иттеләр. Кыш буе тынчу мәдрәсәдә ятудан аксылланып калган йөзләренә шаянлык, мутлык төсмерләре җәелде, аяклар үзләреннән-үзләре Сакмарга, әле кайчан гына дәү-дәү бозлар актарылып-кайнап аккан елгага таба йөгерделәр. Киртә, читән буйларында әлегә кояш нурларына бирешми маташкан кар ята. Башка вакытта булса алар иркенләп кар атышлы уйнап

алырлар иде, бүген исә вакыт юк, үтә әһәмиятле нәрсәне күрми калабыз дигәндәй, йөгерә-атлый Сакмар буена җилдерделәр. Язгы ташу ел саен тар гына күперне үзе белән ияртеп алып киткәч, бердәнбер кичү чарасы — паром кала. Малайлар ак-кара күрми нәкъ менә шушы паром борынын китереп төртә торган сөзәк яр буена, Каргалы халкы әйткәнчә — пристаньга юнәлделәр.

Авыл читенә чыгуга гаҗәеп манзара ачылды. Сакмар елгасы шундый тулышкан, шундый гайрәтләнгән, елга төсен җуеп, җәйрәп яткан диңгезгә әйләнгән иде.

Авыл читендәге сөзәклектә мәхшәр. Монда малайлар бөтенләй белмәгән яклардан килгән йөзләрчә олау Оренбур ягына чыгу өчен атналар буе паром көтәләр. Аргы яктан да шундый ук олаулар, атлар, кешеләр шәйләнә. Язгы ташу беткәнче өйләрендә генә ятсалар ни була торгандыр?..

Малайлар олауларны читләтеп үттеләр. Якын елышмавың хәерле, чөнки Каргалы элек-электән үзенең угрылары, ат караклары белән дан тоткан авыл. Кем булсын: малай-шалаймы, яшьләр яки өлкәннәрме, олауларга якынлаша башласа, ачулы-янаулы тавыш ишетелә башлый. Әллә кайдан, ерактан урап үткән сыман тоелганнар иде, малайларга каршы бер адәм чыкты.

— Малай актыклары, таешыгыз моннан! Көшегез, көш, Каргалы чәүкәләре! Туйган инде сезнең ише ыбыр-чыбырдан. Йөккә җилләре генә тиеп китсә дә, зыян салалар, мур кыргырлары. Әнә бер хәерсезе йөк бавын кисеп, нәрсәдер актарып азапланган.— Елга ягыннан һәрдаим исеп торган салкынча-дымлы җилдән бите кәшәләнеп беткән йөкче нык кына сүгенеп куйды.

Аңа атна буе җүнләп йокы күрмәүдән иңке-миңке йөргән икенче йөкче кушыла:

— Берүк сак бул инде, агай-эне. Үткән ел шушы Каргалы кичүендә мин ярты олау малымнан колак кактым. Чират көтеп ята торгач, арылганмы, Ходай зиһеннән аерып торган чак булганмы шунда, йокымсырап киткәнмен, рәхмәт төшкере. Юлдашларым таныш-әшнә адәмнәрие юкса, алар да искәрми калганнар.

— И-и туган, йокы белән үлем бер. Ярый, бөтен малыңа каз мае сөртмәгәннәр...

— Йокы дип, бер күзем ачык, бер күзем ярым йомык, черем итү инде. Үзем күреп торам, ике адәм килеп, йөкне актаралар, шуларга кычкырып кына булмый. Оеп тик ятам, әллә чын хәл, әллә саташам мин әйтәм. Һушка килеп, сикереп торган идем, кая ул, тегеләрдән җилләр искән.

— Угры сине көтеп тора ди.

— Әй үзәкләрем өзелде инде...

Олаучыларны тыңлап торуы рәхәт тә, монда буталып йөргә вакыты ул түгел. Малайлар күнегеп беткән инде, мөсафирларның үзләренә карата коры кыланып, читкә тибәрүләренә артык исләре китмәде. Үз юллары юл, пристань ягына теркелди бирделәр.

Монда да кызык. Елга агышын басып, шау-шу килә халык. Кемдер чиратын югалткан, кемдер хәйләгә керешкән: хәрәмләшеп паромга алданрак үтмәкче була. Теге як ярга барып төртелгәч тә, тынычлык юк. Инде хәзер җай гына паромнан чыгып китә алмыйча тарткалашалар. Бусы — үзе бер тамаша. Тик малайларның моны тамаша кылырга вакытлары юк та юк инде. Үзләренә яхшы таныш паромчы Зариф абыйның паром ярга туктаган уңайга, көчле ыргым ясап җиргә сикерүен, паром бавын күз ачып йомганчы «пристань» итәгендәге юан тәбәнәк баганага бәйләп-ныгытып куйганын карап, сокланып торырга була анысы. Зариф абыйлары таза, көчле шул. Соклансаң да була! Яр буенда бераз юангач, букчаларын якындагы җимерек күпер араталары астына яшереп, ерак түгел кузна уйнаучы малайлар янына йөгерделәр. Караңгылар төшә башлаганчы уйнап, хәлдән таеп, язның бу көнен шулкадәр күңелле, мәгънәле үткәрүләренә сөенеп, күпер буена килсәләр, акылга сыймаслык хәл — күпернең теге калдык өлеше биек ярдан аска, болганып аккан Сакмарга җимерелеп төшкән дә киткән... Киткән икән китә бирсен, әмма Әптери белән Әхмәтсафаның китап, грифель тактасы тутырылган букчаларын да калдыруны кирәксенмәгән күпер, үзе белән иярткән...

Хәлнең мөшкеллеген чамалап, телсез калган Әхмәтсафага карап, Әптери такмаклап алды:

— Бетте баш, малай, өйгә кайтып керде юк! — диде ул, еламсыраган тавыш белән.— Сабактан качканны хәлфә эткәйгә әйтми калмый, болай да эләгә иде, әгәр букчасыз калуны да белсә-ә... Ярачак ул мине, чыелдатып ярачак...

Әхмәтсафа, әтисенең беркайчан да кул күтәрмәгәнен белгәнгә, артык чәпчемәде. Эткәсе еш кабатлый торган сүзләрне әйтеп, Әптерине юатырга тырышты:

— Баш ярылып, күз чыкмаган...

— Сиңа рәхәт, син җүләр, дигәндәй... Атаң тырнак белән дә чиртми бит сезгә. Минем эткәй холыксызлансамы?! «Сыер дуласа аттан яман»,— ди инәй. Юк, син теләсә ни эшлә, мин бүген өйгә кайтып тормыйм,— диде Әптери, ныклы карарга килеп.— Бабайларда кунам, иртәгә, төштән соң, әбекәй илтеп куяр әле өйгә. Эткәй әбекәйдән шөлли, ул булганда дөнья җимерми.

Әптеринең атасы дуамал холыклы адәм иде. Ярачак ул Әптерине, малай дөрес әйтә.

— Мин башка бармыйм сабакка! — диде Әхмәтсафа.— Озакламый сабанга төшәләр, кыр эшләре башлана...

— Шуннан? — диде Әптери, өлкәннәрчә сөйләшергә маһир Әхмәтсафаны бүлдереп.— Сабак бетмәс борын сине кем мәдрәсәдән алсын?

— Башкаларныкы бетмәгәндер, безнеке бетте инде.— Әхмәтсафа көлеп ярга якынрак килде. Шаулап аккан Сакмарга карап уйланып торгандай итте дә көйләп җибәрде:

Китте букча суга агып,
Йөрмим сабакка барып...

Әхмәтсафа сүзендә торды. Шул көннән башлап мәхәллә мәдрәсәсенә бармады. Бәхетенә, көзгә Оренбурдан Мифтах мөгаллим килде. Вәлкәй хаҗи Әхмәтсафаны Мифтах хәлфәгә бирүгә нык каршы булды. Имеш, Мифтах хәлфә малайларны деннән яздырырга, урыс итәргә килгән. Мостафа агай бирешмәде, дөнья булгач, белемнәрнең барысы да кирәк, дип, улын җәдитчә мәптеккә, Мифтах мөгаллим кулына тапшырды.

Таңны сискәндереп, әтәчләр кычкыра башлады. Төн буе төрле уйлар уйлап, җәфаланып беткән Әхмәтсафа йокыга китеп кенә маташа иде, үги әнкәсенең яңгыравыклы тавышы ишетелде:

— Тор, Сафа, әнә Саттарлар җыенып, капка төбенә килеп басканнар инде.

Әхмәтсафа үз-үзен белештермичә сикереп торды, «ә» дигәнче түбәнгә төшеп, юынырга ашыкты.

Шәмсия шаркылдап көлеп җибәрде:

— Юри генә әйттем. Саттар белән Әптери әле җиденче төшләрен күреп яталардыр. Торгач торгансың икән, тиз генә капкалаштыр да мал асларын тазартып куй,— дип, чиләкләрен шалтыратып урам коесына суга чыгып китте.

Бу иртә Әхмәтсафаның балачагы белән хушлашу таңы иде...

## VII

«Хөсәения»дәге тәртипләргә ияләшеп китү башта кыен булды. Күңел гел авыл ягына тарта, ә монда һәр нәрсә хәлфә-мөдәррисләрнең рөхсәте белән генә эшләнә. Әхмәтсафага үзе кебек хәзерлек сыйныфы шәкертләре торган бүлмәдән түгел, ә өченче каттагы, аңа караганда бераз өлкәнрәкләр бүлмәсеннән урын бирделәр. Монда электән килгән гадәт буенча, һәр нәрсә санлы, ягъни номерлы иде. Әхмәтсафа да уникенче санлы ятакта йоклый, ашханәдә уникенче урынга утырып ашый, сыйныфта аның партасы (бу яңа сүзгә ия-

ләшә алмый интекте) шулай ук уникенче иде. Авылдаш малайлар — Саттар, Габдерахман-Әптери, Хәмитләрдән аерыласы килмәгән иде килүен. Хәер, яңа бүлмәдәшләренә дә тиз ияләште ул. Бер ягында — Шарлык ягы егете, инде бу мәдрәсәдә өченче «кыш»ка килгән (ул уку елын шулай «кыш»лап саный иде) Сәгыйть; стена буендагы ятакта — юантык гәүдәле, иреннәре дымсуланып, бүселебрәк торганы Мәҗит исемле егет китап актаргалап ята иде. Сәгыйть Агишев — сөйләшергә ярата торган, җор телле, якты йөзле шәкерт. Мәҗит аның капма-каршысы. Кем ни әйтсә — шуның белән бәхәскә керергә генә торган әтәч холыклы, төртмә телле. Аңа йомышың төшмәсен, ник дәшүеңә үкенерсең. Калган шәкертләр белән тиз дуслашты ул. Мәҗиткә ишарәләп, Сәгыйть берничә төртмә сүз дә ыргытып алды:

— Дөньяда мокытлык дигән чир бар, Әхмәтсафа. Бу чирдән Әбүгалисинаның тыйб китабында бер дәва да күрсәтелмәгән. Димәк ки, юк андый дару. Ни өчен ышанып әйтәм, чөнки мокытлар ул чакта да булган. Даруы табылса, тыйб китабының беренче битенә үк язып куяр иде Әбүгалисина галиҗәнаплары. Мокытка Ходай үҗәтлекне өеп биргән. Син караны кара дисең, ул ак дип сикереп тора.

Мәҗит бу сүзләргә бәйләнергә теләп, кисәк кенә кулындагы китабын бер читкә ыргыткан иде, нидер уйлап, астан гына Сәгыйтькә карап алды да кире ятагына ауды.

Ишек янында тагын бер ятак бар. Анысы әлегәчә буш тора — хуҗасы килеп җитмәгән икән.

Уку башланып, берничә көн үтүгә, шәкертләргә «Хөсәения» дигән атаманы онытырга куштылар: алар укыган белем йорты мәдрәсә булудан туктап, Көнчыгыш халык мәгарифе институты итеп үзгәртелгән, имеш. Озак та үтми, мәдрәсәдә дини йолаларны — намаз уку, ураза тоту, гает көннәре үткәрүне тыйган фәрман язып элделәр.

Беркөнне, фәрман эленгән дивар яныннан үтеп барганда, Сәгыйть туктап калды һәм шыпырт кына әйтеп куйды:

— Мине монда өйдәгеләр мулла булырга дип җибәргәннәр иде, хәерле булсын, бөтенләй динсезгә әйләнеп кайтам инде. Вәт нинди замана килде безгә, дустым,— диде ул, хәсрәтле көлемсерәп.— Бер карасаң, рәхәт бит, мин сиңа әйтим, иртән комган тотып, тәһарәт-мазар дип чабулап йөрисе юк, казыйларның әрләвен ишетеп торасы юк. Каршы төшкән адәм заты да күренми тагын, әйтерсең шуны гына көтеп торганнар. Кешене диннән биздерү бик җиңел икән, иманлы итү генә кыен бәндәне.

Яннарыннан сөйләшеп, басынкы көлешеп, үзләренчә чикылдашкан булып кызлар үтеп китте. Сәгыйть кызларга ым кагып алды:

— Болары оҗмах кошлары була инде.— Ул мәзәк кенә күз кысып алды.— Мин мәдрәсәгә килгән елны бу бинада эзләре дә юк иде. Шәһәрдә аерым кызлар мәктәбе бар иде. Әдәби кичәләр үткәргән чакта, кызларны кунакка дәшик, дисәң, хәлфәләрнең күзләре маңгайга менә иде. Ә кызлар белән танышасы килә, малай. Шуңа күрә әдәби кичәләргә Кәрван-сарайга йөрдек башта. Анда Бабич агай шигырьләр укый иде, ай-вай, вәт галим кеше иде ул.

— Хәзер кайда соң ул? — диде Әхмәтсафа, Бабич турында сүз чыккач, кызыксынуын яшермичә. Шәехзадә Бабич исемле шагыйрь турында аларга Мифтах хәзрәт бик илһамланып сөйли иде. Әхмәтсафаның соравыннан Сәгыйть күңелсезләнеп калды. Кемнәндер шикләнгән сыман, тирә-якка каранып алгач, пышылдап диярлек:

— Үткән ел кызыллар тотып алганнар аны. Башкорт хөкүмәтенә эшләгән икән ул. Башта башкорт хөкүмәте сәвиткә каршы булды, аннары кызыллар ягына чыкты. Бабич тотакка эләккән вакытта башкортлар сәвит ягында иде. Темәстән ни эш беләндер кайтып килгән Шәехзадә агай, кызылларга тап булгач, тимәсләр дип ышанган. Качып-нитеп тормаган, прәме алларына килеп чыккан. Тегене тотып алганнар, җәзалаганнар, ахырда, ат койрыгына тагып йөрткәннәр. Кызыллар ерткыч бит алар, дустым. Һушын җуйгач, атып үтергәннәр. Җәл, бичара...

Каршыларына йомшак басып килүче Мәҗитне күреп, Сәгыйть сүзнең юнәлешен үзгәртте:

— Мәҗит, сиңа «кәтүк»ләрдән сәлам! — дип, баскычтан үзләре яшәгән икенче катка күтәрелүче кызларга күрсәтте.— Берсе бигрәк сине сорап өтәләнде инде, әллә Пәрваз булды шунда. «Мәҗит кая, күренми?» — дигән була. Үзенең күзләре ут яна. Нәрсәдер бар монда, мин әйтәм. Хәбәрен тизрәк сиңа җиткерим, дим. Юкка сорашмыйдыр, мин әйтәм.

Мәҗит, исе китмәгән төсле, кулын селтәде:

— Эһем... «Кәтүк»ләр кайгысы ди монда. Менә хисаптан сабак әзерләп йөрим. Һич баш җитми, ике поезд каракаршы чыга да берсе кызулап китә, берсе нигәдер әкренли шунда. Ничә сәгатьтән очрашалар, имеш. Очрашмасалар, ник дөмекмиләр... Ник кирәк инде ул миңа? Минем паровоз буласым юк лабаса! — дип, кемгәдер бәлаләп, үпкәләп, хәлфәләр бүлмәсенә таба китеп барды.

— Җелегенә үтәләр аның өстәмә дәрескә чакырып,— диде Сәгыйть.— Югыйсә белмәгәне, күрмәгәне юк, ә хисапка башы җитми.

Әхмәтсафаның күңелен кызлар кузгаткан иде. Мәҗитнең хисапка үтмәгән башы кайгысымы монда! Ул янә кызлар турында сорашасы итте:

— Ә «кәтүк»ләр дигәнең — кемнәр инде алар?

Сәгыйть көлеп җибәрде.

— Кызларны без шулай атыйбыз. Бик тере үзләре. Шүредәге кәтүкләр кебек җитезләр. Чак кына кул сузсаң, яшь боландай читкә атылып, чабып китәргә генә торалар. Җитмәсә, бар эшкә сәләтлеләр, ул кичәләрдә күрсәң, малай... Иннек-кершәннәр ягып җиффәрәләр, мин сиңа әйтим... Башта — калфаклар, аякта — читек, өстә — бәби итәкле күлмәкләр, прәме күзләр камаша. Сәхнә уенына хирыслар. Мандолина, пианино уйнап, декламацияләр сөйләп җиффәрәләр, малай...— Аннан, елмаеп, Әхмәтсафага күз кысты.— Менә укулар көйләнеп, шәкертләр белән дуслашып-үзләшеп бет әле, үзең дә шул «кәтүк»ләр тирәсендә чуала башларсың, бик мут егет күренәсең. Бәләкәй буйлы җегетләрне кызлар никтер ярата бит. Мусаны күздә тотып әйтүем. Үлчәп баксаң, буйга сиңа караганда да тәбәнәк иде. Шул бәләкәй генә Муса «кәтүк»ләр тирәсендә йөри торгач, «орчык»ка әйләнде тәки. Кызлар үз иткән егет болай да бер башка үсә ул, мин сиңа әйтим. Һәй, елгыр малай иде Муса. Кызлар сагынып үләр инде. Быел укуга килми ди...

— Ә нишләп килмәскә уйлаган соң ул? — дип сорады Әхмәтсафа. Аның Муса исемле шәкерт турында ишеткәне бар иде. Әллә ничек, үзен күрмичә үк, күңелне җәлеп итә торган исем иде бу. Серле тоела иде Муса атлы егет. Серле нәрсәне тотып карыйсы, җан иясен күрәсе килә бит инде.— Кайсы яктан иде? Кыргыз-кайсак якларыннан түгелдер ич?

— Мостафадан ул, безнең якташ,— диде Сәгыйть. Муса исемле шәкертне дус күрүе, аның исемен аеруча яратып, үз итеп әйтүеннән сизелеп тора иде.— Шигырьләр дә чыгара. Бабич кебек зур шагыйрь булмакчы. Булыр, нишләп булмасын?! Аңа әдәбияттан Шәриф Камал кебек әдипләр сабак биргән. Безгә генә ул... Әллә нигә быел хәлфәләр пошаманда йөргән сыман. Күп укытучылар мәдрәсәдән киткәннәр. Шуңа аптырап йөрүләре микән?..

Алар шулай сөйләшә-сөйләшә үз бүлмәләренә килеп керделәр. Сәгыйть астарсыз, җәймәсез буш караватны күрсәтеп:

— Шушында йоклый иде Муса...— диде. Сагыну хисләре тышка ук бәреп чыкты.— Менә бусы да аныкы...— дип, карават башындагы җыйнак кына сандыкка күрсәтте.— Быел әтисе үлгән аның, шуңа килеп җитә алмады... Абыйсы Ибраһимны күргән идем беркөнне. Ул «Мөхбир» дигән гәҗиттә эшли. Аптыраулы кыяфәттә. «Авылга китәргә туры килер, әткәй вафат бит минем,— ди.— Энекәшләрне, сеңелкәшләрне карау минем өскә калды»,— дип, күз яшьләрен сөртеп алды. Нечкә күңелле егет икән, Муса да шундый

иде. Муса соңрак килә, болай булгач. Ну шәп уйный иде мандолинада. Тотам үзеннән калдырмый сазын. Хәзер авылда уйнарга җае юктыр, әткәсе вафат булгач соң... Бик тә килештерәләр иде Гайшә белән сәхнәгә чыксалар.

Әхмәтсафа ут борчасы сыман җитез, чибәр Гайшә Мөхәммәдова дигән кызны күреп белә иде инде. Сәгыйть дөрес такылдый торгандыр. Шундый кызның күңелен яуларлык булгач ни, шәп егеттер ул Муса.

Сәгыйть Мусаның ятагына моңаеп карап торды да үз урынына китте. Китап-дәфтәр кыштырдатып дәрес хәзерләргә җыенган җиреннән, кинәт башын күтәреп, артистларча килештереп шигырь укый башлады:

Яңгырат илне, алынга чык, себреп ил тапларын!
И уян, ил, бу синең инде уяныр чакларың!
Барча хаклык, барча шатлык дөньясы алда әнә!
Әйдә омтыл шул тарафка, анда алга юл аңа!

Үзенә әсәрләнеп карап торган Әхмәтсафага күзен кысып алды да Сәгыйть янә Муса ятагына ымлады:

— Бу декламацияне Муса язган иде. Менә бит, ничек әйтә!..

— Бабичтан ким түгел...

Сәгыйть илһамланып шигырь укый башлаган мәлдә бүлмәгә килеп кергән, үзен һәрнәрсәдән хәбәрдар дип санаучы һавалы Фатыйх Сәгыйтов иреннәрен бөрештерде:

— Ни-нәрсәсе бар инде бу шигырьнең? Бабич, имеш... Инде дә килеп, Тукай хәзрәтләре, Дәрдемәнд, Сәгыйть Рәмиев белән дә чагыштыр алайса. Хәзер һәркем — мөхәррир, һәркем бәет чыгара. Сәгыйтькә төбәп ике юл шигырь укып алды:

Гаҗәп түгел сабый илә сабыйлык,
Гаҗәптер әмма гамәлдә габилык.

— Әһә,— диде мәгънәле рәвештә Сәгыйть.— Җегетнең түбәтәй асты бөтенләй үк буш түгел. Дәрдемәнд сүзләре аша безне аңгыралыкта гаепләп ташлады әнә. Тик шуны онытма, Фатыйх: Мусаның беренче тәҗрибәләре генә бу. Шәриф абзый аңа зур өмет баглый. Төхфәт Ченәкәй дә олылый үзен. Синең шуңа ачуың килә, әйеме?..

Фатыйх:

—Таптың ачу китерер нәмә! — дип мыгырданып алды. Бүлмәдәге ничә шәкертнең ник берсе аны яклап сүз әйтсен. Моны сизеп, отыры ачуы чыкты. Зәһәрләнеп, бүлмәне бер әйләнде дә, тагын кемгә бәйләнергә белми, бүселеп чыгып китте.

Сәгыйть, Фатыйхның кыланмышына игътибар итмәстән, Әхмәтсафага борылды:

— Ә син үзең шигырь язмыйсыңмы?

— Юк,— диде Әхмәтсафа көлемсерәп.— Бәет чыгармасам да, яттан шигырь сөйләргә яратам, Мифтах мөгаллим үзе дә әдәбиятны яхшы белә иде, белгәнен безгә дә өйрәтергә тырышты.

Сәгыйть шуны гына көтеп торган диярсең. Икеләнергә урын калдырмый, Әхмәтсафаны кыстый башлады:

— Әйдә, малай, сөйләп җибәр әле берәр шигырь, ач күңелне!

Әхмәтсафа ялындырмады, шигырь укый башлады:

Сызла, сызла, сызла, күңлем,
Сызла бертуктамыйча.
Сызла айлар, сызла еллар,
Сызла төн йокламыйча!

Сәгыйть, елмаеп, кулын Әхмәтсафаның җилкәсенә салды һәм кайнарланып дәвам итте:

Сызла, сызла, син мәхәббәт
Ялкынын гөлләр яса.
Мәңге хәсрәт һәм кара төн
Елларын көннәр яса!..

— Афәрин, туган! Их, шушы мәлне Сәгыйть хәзрәт Рәмиев үзе күрсә!.. Синең белән яшәргә була,— диде ул, Әхмәтсафаның җилкәсенә кагып.— Әдәби кичәләр башлансын гына, шиксез, сәхнәбезнең яңа бер йолдызы булачаксың! Сиңа урын түрдән, дустым. Тагын ни гамәлләр беләсең? Ходай бер биргәнгә өеп бирә бит ул...

Әхмәтсафа, мактаудан күңеле булып, тиз генә аяк киемен салып ташлады. Куллары белән идәнгә таянып, аякларын төп-төз өскә күтәрде һәм, барсын да шаккатырып, җиңел генә кулларында йөреп китте. Моны физкультура дәресләрендә һаман да шул Мифтах мөгаллим өйрәткән иде.

— Булды, җитте, малай,— диде Сәгыйть, кулларын шапылдатып.— Синең кебек маймылланучы юк иде әле бездә.— Ул шаркылдап көлеп җибәрде.— Чын артист икәнсең!

Берничә көн үткәч, моңарчы хәзерлекнең беренче сыйныфында йөргән Әхмәтсафаны, керү имтиханнары вакытында әйтелгәнчә, икенче сыйныфка күчереп куйдылар. Ул — Гайшәләр укыган сыйныф иде. Беренче тәнәфестә үк, иптәш кызын җитәкләгән Гайшә әле сыйныфташларына ияләшеп җитмәүдән кыенсыныбрак торган Әхмәтсафа каршысына килеп басты.

— Дустым,— монда укучы кызлар да, егетләр дә берберсенә шулай эндәшергә күнегеп киткәннәр иде,— ишет-

терделәр, оста итеп декламация сөйлисең икән, аннан гимнастик күнегүләр ясарга да маһир, диделәр...

— Кем әйтте? — диде Әхмәтсафа, гаҗәпкә калып.

— Сүз иясе белән йөрми...

Ул каршысында чытлыкайланып торучы Гайшәнең тел төбен аңлап бетерми иде әле. Ә менә Гайшәнең иптәш кызы... Кызга бер караш ташлау белән Әхмәтсафаның йөрәге җилкенеп куйды. Озынчарак алсу йөзенә им өчен генә дигәндәй, бераз гына сипкел сипкәннәр шикелле. Шундый сипкелле кыздан да сөйкемле кыз юктыр дөньяда! Кыз үзе дә озын керфекләре арасыннан егеткә бер караш ташлап алган булды. Битендәге алсулык куера төште. Кыз егетнең карашын тотып алып, оялган рәвешле, күзләрен түбән текәде.

Гайшә, үзе әйткәнчә, малай-шалай белән аралашып өйрәнгән, Әхмәтсафаның күңел түрендә мизгел эчендә уйнап алган хис өермәсенә исе дә китми, сөйләвен белде:

— Үзешчән сәнгать түгәрәге эшен яңартып җибәрәбез, дустым.— Акыл сатып та алды.— Монда кыш буе таракан симертергә килмәдек, мәгърифәт нуры җыярга килдек. Үзебез йөрмәсәк, бер нәрсә дә китереп бирмәсләр безгә. Менә Заһидә,— ул янәшәдәге кызга җиңелчә генә терсәге белән төртеп куйды,— матур итеп җырлый. Бии дә белә...

Заһидә, кашларын җыерып: «Нигә әйттең инде?» — дигәндәй, назлы тавыш белән сузып:

— Гайшә-ә! — дигән булды. Бу сүзләр ахирәтенә кисәтү ясаган кебек яңгырады.— Әле бит...

— Бетте, бетте,— диде Гайшә көлеп.— Нәрсә җебеп төштең әле Әхмәтсафа алдында? Егетләр күргәнең юкмы әллә?

Тегесе бөтенләй оялып, читкә тартылды.

Гайшә бу хәлгә бик канәгать иде бугай, Заһидәнең беләген тагын да кысыбрак тотты:

— Менә парлашып сәхнәгә килеп чыгарсыз әле, шәкертләрнең күзләрен яндырып! Киләсе атнада түгәрәк эшен башлап җибәрәбез, беренче утырышка Шәриф агай белән тагын берничә кунак чакырабыз. Сез...— Әхмәтсафа белән Заһидә кире уйламаслык итеп әйтәсе килә иде аның. Тавышында катгыйлык чаткылары пәйда булды.— Сез быел концерт-тамашаларны алып баручы булырсыз! Үткән ел кичә саен алып баручы эзләп хәлдән тая идек...

Шушы көннән башлап Әхмәтсафаның күңеле әллә нишләде. Заһидәне гел күреп торасы килә. Үзе генә сизеп бетермәгән: моңарчы аның җаны йокымсыраган булган икән бит. Хәзер җаны уянып, дөньясын яктыртып, ямьләндереп җибәрде.

## VIII

Кышкы каникулдан Әхмәтсафа күңелсезләнеп килде.

Кемнәндер ат алып әтисе аны Оренбурга үзе китереп куйды. Туры мәдрәсәгә төшермичә, Гомәр агаларына алып китте.

Сирәк кунакларны Гомәр абзый шатланып каршы алды. Шулай да аның күңеле тыныч түгеллеге күренеп тора иде.

— Сәүдә эшләре көяләде, Мостафа туган, — диде ул, кунаклар чәй эчәргә утыргач. Мостафаның да йөзендәге сүрәнлекне шәйләп алгач, сүзе өзелеп калды.

Мостафаны аңларга була. Гомер буе тире-яры белән эш иткән адәм ич ул. Соңгы елларда бөтенләй сәүдәдән читләшеп калды менә. Шуңа пошына, үз-үзен эчтән кимерәдер, бахыр. Ул гына җитмәде, өйләре янып көл булды, бусы да зур каза. Гомер иткән хатыны үлеп, яңадан өйләнеп, аякка басып кына килгәндә афәткә тарыды шул. Каргалыда янгыннар чыгып торды инде ул моңарчы да. Гомәр үзе дә шаһит, уникенче елгы янгында халык, ут-эссегә чыдый алмагач, Сакмарга кереп тулды. Ике сәгать эчендә авылның яртысы янып бетте. Тагын хафаландырганы шул — Мостафаның яуга киткән улларыннан хәбәр юк, ди. Ата кеше моңа да борчыла... Гәҗитләр караштырганда, Гомәрнең күзенә чалынды, Усманов төзегән гаскәрләр хәзер Бохара, Хива ханнары белән алышта икән. Гомәрхан белән Госман шунда барып эләккәннәрме, башка җирдәме?.. Исәнме алар, үлеме?.. Кем дә белми. Шушы нәрсәләр Мостафаны тәмам сындырып бетергән булса кирәк. «Бирешкән энекәш, нык йончыган», — дип уйлады Гомәр.

Әмма Гомәр абзый уйлаган сәбәпләр җитди, бик җитди булса да, Мостафаның эчен тырнаган, йөрәген әрнетеп торган тагын бер сәбәп бар иде — ул Шәмсия...

Хатынның үзенә яучы җибәреп, биш бала өстенә үги әни булып килүенең серен белә Мостафа. Шәмсия беркөнне нигәдер бу хакта аның үзенә сөйлисе итте. Вәлкәй хаҗи, үтә әрсезләнеп, Шәмсияне икенче хатынлыкка сорый башлагач, яшь хатын чарасызлыктан, куркудан: «Әгәр шушы карт үләттән котылсам, биш бала белән тол калган иргә кияүгә чыксам да үкенмәс идем!» — дип, нәзер әйткән булган. Нәзер әйтүе хакында күрше диярлек яшәгән Тайфә карчыкка ычкындырган. Тайфә карчык, дөньяның ачысын-төчесен күп татыган карчык, Шәмсиянең яшьлек гүзәллеге сирпеп торган йөзенә, килешле сылу гәүдәсенә карап-карап торган да кызганып елап җибәргән. Аңа Шәмсия кушылган. Икәүләшеп туйганчы яшь түккәч, карчык телгә килеп, хатынны тынычландырырга тырышып караган:

— Бетеренмә, кызым... Насыйбың кемдә — Ходай шуңа пар итәр. Баш ярылып күз чыкмаган, тол хатынга хәбәр салучы күп булыр инде. Хәзрәтләрнең дә күзе төшә торгандыр, сала мажиклары да шундый чибәр хатынның япа-ялгыз яшәп ятуына тыныч кына карый алмыйлардыр. Өмет итеп, капкаңны кагып, ишегеңне шакып караучылар юк түгелдер. Тик нәзер әйтеп, үзеңне нәзер корбанына әйләндерү килешми, кызым. Китап та кушмый, нәзер әйтү белән шаярмыйлар. Син дә бу эш белән уйнама...

— Уйнамыйм, чын йөрәктән әйтәм,— дигән Шәмсия, һаман күз яшьләренә буылып.— Нишлим инде, әбекәем, Вәлкәй хаҗи көн саен кеше җибәрә өемә. Үзе дә кереп чыкты. «Риза булмасаң, исемеңне дөньяга чыгарып, адәм рисвае итәм»,— дип яный да башлады. Чарам юк, әбекәем, зинһар, бер киңәш бир. Башымны шул чалмалы шайтан ашар микәнни инде, ә? Нәзерем шул, Тайфә әбекәем, тол, төскә-биткә ямьсез булмаган ир булса, биш бала өстенә дә барырга риза! Үлсәм дә Вәлкәй тәрегә бармыйм. Икенче хатынлыкка да риза түгел мин. Кем сораса да...

— Һай, балакаем, хаҗи тиклем хаҗи кешене «чалмалы шайтан» дип хурлама син. Ходайның кемне сөйкемле сөяге иткәнен, кемне нинди гөнаһлары өчен мәңгелеккә тәмуг кисәве итәсен белгән юк. Әгәр инде бик ашкынсаң, җаны теләгән җылан ите ашаган, ди, әнә урам башында гына ялгыз яшәп ята Мостафа. Ир дисәң дә ир инде үзе. Маһинур вафатыннан соң, бичаракаем, башын күтәреп кояшка да карамый. Балалар мәшәкате басып киткән үзен. Кайчан карама, күңеле тулы гамь булыр. Теләсәң, хәбәр салам.

Шәмсия үрләп киткән хисләрен тыя алмый, Тайфә карчыкны кочаклап ук алды:

— Нәкъ мин уйлаганны әйттең, әбекәем. Барчале, хәбәр салып кара шул Мостафа абзыйга. Ул картайган-бөкрәйгән кеше түгел, риза булса, рәхәтләнеп яшәрбез.

— Алла боерса, диген кызым. Фәрештәләрнең амин дигән чагына туры килсен ниятең.

Шәһәр йортларын өнәми Мостафа. Авыл өендә ниндидер аклык, яктылык бар. Күпме вакыт Гомәр абзыйсын, инде яше алтмышны узып барган, халык арасында абруй-дәрәҗәсе булган гыйлем иясен, нәселләренең алтын баганасы саналган мөхтәрәм затны тыңлап утыра, өйдәге сүрәнлек күңелгә үтеп керә, кисәк-кисәк сүзнең җеп очын югалта, әңгәмәнең төмен тоймый. Җанда — шәһәр өйләрендә генә була торган зиһенне сыеклатдыра торган шыксызлык. Һавасы дымсу, күгәрек исе килә, тын җитми. Шәһәр кешесенә Ходай ярдәм бирсен инде... Мондый чакта сүз берекми.

Мостафаның уйлары тагын Шәмсия тирәсендә бөтерелә.

Хатынга карата битарафлыгын һичничек тә аңлата алмый. Шәмсия аның өчен Ходай тарафыннан җибәрелгән иң зур бүләк булырга тиеш югыйсә. Күз ияләнсә дә, күңелне күндереп булмый икән, шушы яшь, чая, дәртле хатынны да онытылып ярата алмагач соң... Гаҗәп инде, гаҗәп. Мостафа җиң сызганып сәүдә белән шөгыльләнгәндә, бу хакта артык уйланмый иде. Эш барысын да оныттыра. Үзенә күрә мавыгып, адарынып йөрисең. Керемне санийсың, чыгымны чутлыйсың, эшләр хөртиләнгән кебек булса — янасың-көясең, аз-маз табыштан да башың күккә тия, дөньяның бар рәхәте шулдыр кебек тоела. Көз көне, кыр эшләре бетеп, казакъ далаларына чыгар чак җитсә, Мостафа сөенеп йөри. Җанында әйтеп бетергесез ләззәт, җилкенү сизеп, күңеле канатлана, ул инде кеше заты түгел, очар кошка әверелә, иксез-чиксез далага тартыла, иләсләнеп, офыклар аръягына талпына иде. Шәмсияне калдырып, аннан аерылып торуны ул һич кенә дә сөенеч дип кабул итми. Алай дисәк, дөреслеккә хилафлык китерү булыр иде. Шул ук вакытта, өйдән чыгып китү җанына ниндидер җиңеллек тә китерер кебек. Бәлки, сәүдәгә хирыслыгы дөнья гамен томалап, барсын да артка табан этәрә төшә торгандыр? Ияләнгән күңел мохитеннән колак кагу — менә шушы шәһәр йортындагы шыксызлыкка түзеп яшәүгә бәрабәр инде. Мондый тарлыкта иң беренче югалткан нәрсә — җан сәламәтлеге. Җан сәламәтлеге булмаса, тән сәламәтлеге булмый тек булмый инде. Аннан беттем диген.

Баштарак Шәмсия иренең шулай вакыты-вакыты белән өйдән чыгып китәргә ашкынып йөрүенә үрсәләнсә дә, тора-бара күнектеме, Мостафа юлга җыена башласа, тыннары кысылып, алда үзен ниндидер рәхәтлекләр көткән кебек, җиңеләеп китә иде. Аяк атлауларына кадәр үзгәрә. Үкчәсен бәреп, нык басып йөрергә күнеккән хатын шундый йомшак атлый башлый, күлдә йөзгән ана үрдәкмени! Хәлфетдин генә хуҗа сәфәргә җыена башласа үтә җитдиләнә. Ул хуҗаның сәфәргә алып чыгасы һәр нәрсәне үз кулы белән барлап, кат-кат күз уңыннан үткәрә. Аеруча камыт-ыңгырчакларны барлый, рәткә китерә. Дөрес эшлимме дигәндәй, астан гына хуҗага күз төшереп ала. Мондый хезмәтчегә тел-теш тидерерлек түгел, әлбәттә. Әгәр сәүдәгә чыгып киткән хуҗа ярты юлдан арба-фәлән ватылып, кире борыла калса, ник кирәгең бар синең? Андый эшнең хәере булмый, сәүдә барып чыкмый юлда кире борылсаң, моны Каргалыда сабый бала да белә. Сәүдә булмагач, көнлекче булып эшләүнең дә кирәге калмый. Хәлфетдиннең чырышлыгын аңларга була. Юлга җыенганда, Шәмсия буталып йөрүдән шүрли кебек, аның барлыгы да беленми. Хатыны ара-тирә күзенә чалын-

ганда, Мостафа нидер әйтергә теләгәндәй авызын ача да тамагына бәрәңге утырган шикелле катып кала. Ичмаса ник бер сүзе булсын!.. Үзенең сәер хәлдә калганын Шәмсия абайлап алганчы, ишегалдына атылып чыга. Атларны сугара, аларга азык салып, озак кына юанып өйгә керә. Бу вакытта инде тынычланган, басылып калган кебек була.

Мостафа шулай күтәрелми-бәрелми, күп сүзгә җитми генә юлга җыена. Өйдә калучыларның һәркайсында соңгы вакытларда булып алган сизелер-сизелмәс үзгәрешләр аңа бөтенләй кагылмый кебек. Аның бернәрсәдә эше юк, ныклап кар төшеп, дала юлларын күмеп бетергәнче казакъ аймакларына барып җитәргә кирәк. Шул гына эчен пошырса пошыра. Анда сугым чорын үткәреп, йөк-йөк тире-яры җыеп, хут суыклары үткәч, Оренбурга кайтып керер ул, боерган булса. Казакъларда мал күп елны, җыйнаган чималны юл өсте туры килсә, Троицк, Орск калаларына тапшырган чаклары да була. Оренбурга язга кергәч кенә әйләнеп кайта андый елларны. Менә шул чагында гына тынычлана инде аның күңеле. Җирләр гизеп, арып-талып үз өенә, балалары янына кайтып егылган мәлләр аның өчен иң кадерле, иң кыйммәтлесе инде. Йөргән аякка төк иярә, буш кесә белән кайтып керми иде ул. Берәр атна ял итәме, юкмы, Оренбурга барып, мал төяп, Уфа якларына чыгып китә, юллар өзелгәнче тагын кәсеп итеп, шактый гына мая туплый. Шөгыльләр арасында бары тик сәүдәне генә дәрәҗәле эшкә саный ул. Хатыны Шәмсия белән аралары көйләнеп бетми икән, анысына да артык бетеренмәде. Иң мөһиме: кул арты китмәсен дә сәүдәләр гөрләп барсын... Дөньялар үзгәрмәсә, эш шулай барыр иде дә. Барсының асты өскә килде әнә. Атсыз-нисез, бер байгыш хәлендә калып йөрүе авыр, һай, авыр икән. Ни сабыр Гомәр абзый да сүзен сәүдәнең көе китүеннән зарланып башлады. Юкка түгел бу. Алда аз гына яктылык күренсә дә, Гомәр абзый болай ук бәрелмәс иде. Әмма болар аркасында гына түгел Мостафаның күңелсезләнеп калуы.

...Беркөнне Шәмсия ис китәрлек яңалык җиткерде:

— Фәтхулладан хәбәр килгән, исән икән,— диде ул, иңрәүле тавыш белән.— Теге Биккол адәмен җир йотсын! Фәтхулланың үлгән хәбәрен китереп, бөтен зиһенемне алды. Җанымны кыйды бит, җанымны кыйды. Үзе дә инде. Ничә еллар хат язмый торды. Менә хат җибәргән. Себердә аклар белән эшне бетердек, озакламый кайтып җитәм, дигән...— Шәмсия сүзен әйтеп бетерә алмады, үксеп елап җибәрде. Мостафа аяк астындагы идәннең кай яккадыр шуыша башлавын тойды. Өй эчендә сүстән бау ишеп маташа иде, кулының җегәре бетеп, яртылаш ишелгән бау идәнгә шуып төште. Хәзер инде аның ни аты юк, ни сәүдә эшләре алып барырга

җай бирми бу хөкүмәт — бау ишеп, шуны каладагы бер артельгә тапшырып, көнне-көнгә ялгап яткан мәле иде. Ул беренче мәртәбә шулай текәп, озак кына карап торды Шәмсиягә. Кем җиткергән аңа бу хәбәрне? Фәтхулланың үлде хәбәре килгәненә биш еллап бит инде. Герман сугышына киткән кеше ничек Себергә барып эләккән дә ни рәвешле аклар белән эшне бетергән ди? Дөрес сөйлиме Шәмсия?! Әллә Мостафа белән җаннары берегеп җитмәгәнне аңлап, шушы сәбәп белән араны өзү, өйдән чыгып китү җаен карыймы? Ул исәнгерәп, аптырап озак торды. Шәмсия, Хәлфетдин юкка чыккач, шактый көйсезләнеп йөргән иде. Үртәлеп, хафага төшеп айлар үткәрде. Инде бераз тынычланды кебек иде, менә сиңа мә, тагын бер хәбәр. Хәлфетдин өчен Шәмсиянең нигә ул кадәрле эчтән януын, ут йотуын аңлап җитмәсә дә, Фәтхулланың әлеге хәбәре тормышны бөтенләй эздән чыгарасы көн кебек ачык иде. Болай да башны кая куярга белми йөргән чак иде шул. Эшләр әнә кайсы таба бара — авылда гына ничә комитет, ничә сәвит. Мал-мөлкәтеңә хуҗа булып булмый, барсы да сәвиттә исәптә. Балаларыңа да сәвит хуҗа, ди. Бала туса, муллага исем куштырганчы, сәвиткә барып баланың исемен яздырып кайтырга дип әйткәннәр, ди, сәвит корчаңгылары. Хатының да үзеңнеке түгел икән инде, әгәр бераз әфсен-төфсеннәп, хәләл җефетеңнең җеннәрен качырып алсаң — беттең дигән сүз. Сәвит килеп, аерып та куя. Хәер, Мостафа беркайчан да моның ише белән шөгыльләнмәде, аңа мондый куркыныч янамый кебек. Ну инде әгәр бабайлар ысулы белән җәмәгатеңне акылга утыртсаң, хәлләр бөтенләй икенче төс алырга мөмкин. Әйтик, шуннан соң хатының авылдагы хатын-кызлар комитетына чыгып йөгерде, ди. Комитет — сәвиткә ишеттерә. Озак та үтми, өеңә хәтәр бер комиссия килеп керә. Әгәр комиссия «өшкерү» эшләрен чамадан артык дип тапса, ир кисәген мылтыклы солдатлар озатуында төрмәгә үк җибәрергә дә күп сорап торыш юк. Бәс, шулай булгач, Шәмсиягә: «Фәтхулла исән»,— дип, алдашуның нигә кирәге бар? Теләсә болай да чыгып китә. Мостафадан курыкса, сәвит яклавына исәп тота ала. Ирләрнең генә бер хокуклары юк менә. Китәм, дисә, каршы төшеп булмый... Алай түгел икән шул. Янында йөргәндә генә кадерен тоймаган Шәмсиянең. Хатын аңа үз аягы белән килеп кергән мал сыман тоелды, ахры. Андый малның кадере булмый бит. Менә инде икенче мәртәбә шундый тойгы кичерә: беренче тапкыр унтугызынчы елның язында, алмагачлар чәчәккә төренгән иртәдә бар күңелен айкап ташлаган иде шушы сүз. Инде менә бүген... «Фәтхулла» дип авызын гына ачкан иде Шәмсия, Мостафа коелды да төште. Унтугызынчы елны ул көнне авылда ян-

гын чыккан иде. Бу юлы инде ут Мостафаның йөрәгенә капты. «Фәтхулла исән... Димәк, кайтып керәчәк ул көннәрдән бер көнне. Ни дип җавап бирер?.. Шәмсия ни кылыр?» Шушы минутта аңа Шәмсиядән дә кадерле кеше юктыр сыман тоела башлады. Булганда гына кадере беленми икән, югалта башласак...

Шәмсия элек тә Фәтхулланың инде олыгаеп барган әти-әнисен, ягъни биатасы белән бианасын ташлап бетерми иде. Таба ашы пешерәме, гает көннәре буламы, йә башка бәйрәмме — тәмле ризыктан калдырмый иде аларны. Фәтхулладан хәбәр алгач, көн саен диярлек Каргалы очына — башта килен булып төшкән йортка китеп югала. Шунысы бар: бер чакта да Бибкәйне үзеннән калдырмый, әллә ниләр сөйләшә-сөйләшә көлешеп чыгып китәләр, күтәренке күңел белән кайтып керәләр. Мостафаның ут йотып йөрүе әллә бар Шәмсиягә, әллә юк. Хатынны исә бер генә уй көйдерә — Фәтхулла кайтып төшсә, ничек дип җавап тотасы? Кайгырып, бер-ике көн яшь койды, аннан бер карарга килде, ахры. Нинди карар ул — Мостафага караңгы иде...

Шәмсия Мостафа белән араны өзүдән сакланып тора — Фәтхулладан хәбәр килде дә бетте. Башка бер төрле хәбәре дә юк, үзе дә кайтып төшми. Сабыр итми чара юк, чөнки хатынның җанын талкып торган бер нәрсә бар — ул да булса Ходайга ялвара-ялвара әйткән нәзере. Нәзер бозуны иманнан язу белән бер, диләр, үзең сакла Ходаем, ялгышулардан...

Гомәр абзый сөйли дә сөйли... Кунак үзенчә тыңлап утыра, ара-тирә урыныннан калгынып куя. «Дөрес сөйлисең, абзый, синең белән килешәм»,— диюе бугай. Мостафаның күп сөйләшмәвен белгән Гомәр абзый калганына артык әһәмият итеп тормый инде.

Мостафа һич кенә уйларыннан айный алмый. Әйтерсең менә шулай уй эчендә изаланып утырыр өчен килгән Оренбурга. Үз-үзен җиңеп, уйларын куып, тиз генә кире кайтмаслык итеп олактырып бетерә алмады тәки. Һаман шул Шәмсия сәбәпче. Урыныннан купкан җанын янә бер нәрсә борчый — ул да булса, соңгы вакытларда Әхмәтсафага кырын карый башлады Шәмсия. Исең китәр, башка хатыннар артык сәвитләшеп барганда, Шәмсия ничектер моңарчы күзенә артык бәрелми иде, үтә диндарланып китте. Әхмәтсафа турында сүз чыкса, Мостафага бәйләнә башлый:

— Динсез, имансыз булып үсә ул малаең! — ди ул зәһәрләнеп.— Анда Оренбурда «Хөсәения» мәдрәсәсе дигәннең исеме калса да, җисеме калмаган икән. Яшьләрне җыеп, урыс ясап яталар икән хәзер. Кеше арасына керер хәлем юк, абыстайлар, ил карчыклары күземне ачырмыйлар. Моста-

фага әйт, күрә торып, баласын диннән яздыра, диләр. Авылда яшьләр котыра, кәмсәмүл төзибез дигән булалар. Төзерләр, төземи соң — саман сугып, өй җиткереп керәсе түгел бит. Әхмәтсафа кайтса, шулар белән мәш килә. Дәүлине ак йортыннан куып чыгарган сәвит. Шул йортны яшьләр ызбасы иткәннәр. Кайткан саен, шунда кичә-мичә оештырып, декламация сөйләп, яшьләрне котырта, юлдан яздыра, дип сөйлиләр. Яшьләр ызбасы түгел ул, имансызлар ызбасы! Син, ичмасам, Әхмәтсафа белән нык кына сөйләшәсе урынга, шуның кыланмышларына бер кәлимә сүз әйтмисең,— дип колак итен ашый.

Мостафа ай-ай ярым эчендә танымаслык булып үзгәргән хатынын тынычландырмакчы булып маташа:

— Дөньялар гел башка бит, карчык. Әхмәтсафаны тыям дип, өйдә бикләп яткырып та булмый. Элекке тормыш кайтса икән дә... Юк инде, кайтмас. Илне нигезеннән үк җимерделәр. Мин кәсептән колак кактым, Әхмәтсафа шушы тормышка җайлаша алмаса, нишләрбез соң без?.. Безнең нәсел гомер-гомергә сәүдә кәсебендә булган. Мәчеткә тиешле садаканы биреп бардык. Мулла-хәзрәтләр тел-теш тидермәде безгә, иман юлыннан язасыз дип әйтмәде, Ходайга шөкер. Әхмәтсафа да динсез булмас, яшьлек чоры үтәр, эзгә төшәр ул. Яшь чакта була инде ул. Әле хәтеремдә, яшьлектә, никрут булып йөргән чакта, олы хәзрәтнең өй турыннан кич җырлап үткән идек:

Турыгыздан җырлап үттек,
Ачуланма, хәзерәт.
Яшь чактагы җүләрлекне
Беләсең бит әзерәк.

Иртәнге намазда әткәйгә шелтәләп кенә әйткән хәзрәт. Тавышны зурга җибәрмәде тагын. Элек тә яшьләр шулай хикмәт чыгарып куялар иде. Әхмәтсафа да бу шаукымланып йөрүен ташлар. Менә Гомәрхан, Госманы кайларда, хәбәр-хәтерләре юк. Сугышлар да бетеп бара бугай, илгә кайтучылар ишәйде, юк малайлардан хәбәр, юк кына...— дип, сүзгә нокта куйган иде ул чакта Мостафа. Шунысы кызык, әлеге сөйләшүдән соң Шәмсиянең диндарлыгы да чигә төште...

Чәй эчеп бетергәнче, Мостафа шулай үз уйларына чумып, Гомәр абзыйның сүзләрен колак тирәсеннән шудыра биреп тик утырды. Гомәр абзый берара Мостафага күз ташлап алган иде, тегесенең уйлары белән бу өйдән шактый ерак җирләрдә йөрүен аңлап, хәсрәтле генә көлемсерәп куйды. Моны сизеп алган кунак, башын түбән иеп, сансызлыгы өчен гафу үтенгәндәй итте.

Әхмәтсафа чәен эчеп бетереп, өлкәннәрне көтеп тормастан амин тотты да, түр ягына чыгып, ниндидер китаплар актара башлады. Гомәр абзый белән Мостафа агай, өстәл яныннан кузгалмадылар. Чын әңгәмә яңа башланып кына килә әле. Алар еш очраша алмыйлар, очрашсалар серләре килешә иде моңарчы.

— Егетне укытырга кирәк,— диде Гомәр абзый. Мостафа өйдәге хәлләрне сөйләп бирмәсә дә, нәкъ кирәкле җиргә китереп басты. Һаман да үги әнкәсе каршы килсә, Мостафа Әхмәтсафаны бер-ике ел көнлекче итеп йөртү ягын да уйлап куйган иде.— Егетнең үзенә дә әйттем, дөньялар ничек кенә болганса да, барыбер безнең нәсел арбадан төшеп калмады, иҗтиһад иттек. Патшага да ярадык, санатка да ярадык, сәвит белән дә телгә килмәскә кирәк. Мин шулай уйлыйм. Шунысы бар, сәвит башта халык дип күп шаулады шаулавын. Хәзер башкачарак сайрый. Сәвитнең төп таянычы — ярлы-ябагай, имеш. Йә, әйт, әгәр иҗтиһад итә торган булса, гыйлемле, мәгърифәтле булса ярлы, гидай булып йөриме бәндә?

Мостафа «юк» дигәндәй башын чайкап куйды.

— Вәт шул, җырда да әйткәннәр:

Иҗтиһад ит, эшкә башла,
Гомер узып барадыр...

— Үзең йөрмәсәң, Ходай китереп бирми инде,— дип сүзгә кушылды Мостафа, әкрен тавыш белән.— Шунысы гына эчне тырный — яшьләрне мәчет-мәдрәсәләрдән читләштереп, диннән аерып, хөкүмәт ни-нәрсә уйлый икән? Имансыз бәндәләр белән тормыш корып булыр дип саташа микән? Без, сәүдәгәрләр, дингә ябышып ятмасак та, шөкер, иманнан язмадык анысы.

— Сәүдә ул, Мостафа туган, пәйгамбәрдән калган шөгыль. Бер надан: «Шайтан башка, җен башка»,— дип әйткән, ди. Большевиклар тәүге нәүбәттә мөселман дип гаскәр тупладылар, хәзер мөселман дигәнне инкарь итеп, эшче-крестиян дип кенә җибәрәләр әнә.

Мостафа сүзгә кушылды:

— Мөселманнарны бергә туплап, кызыл гаскәр оештырып йөргән Усманов дигән адәмнең сөйләгәне истә: «Без, большевиклар, мөселманнарга һәрьяклап ирек бирү өчен көрәшәбез»,— дип әйтә иде ул.

— Хәйрулла хәлфәнең малае инде ул,— диде Гомәр абзый көлемсерәп.— Әткәсе укымышлы, белдекле хәлфә иде, улы коммунист булды да куйды. Әнә Бохара якларын пыр туздырып йөри икән хәзер. «Диннең оясын тар-мар итәбез!» — дип язганнар гәҗиткә.

— Бохарага ук барып җиткәннәр, диген. Коммунист белән большевиклар дигәннәре ничегрәк соң аларның? Кайсы яхшы, кайсы начар безнең өчен? Дингә кайсы каршы?

Гомәр абзый йөзен чытып куйды да җитдиләнеп җавап бирде:

— Ике чабата бер кием, Мостафа туган. Халыкны гомер иткән диненнән яздыру өчен Ленин-мөртәт икенче дин — большевизм динен уйлап тапты. Хәзер халыкның аңына шушы алласыз динне сеңдерәләр. Бутала халык, кыйбласын югалта. Иң куркынычы шул. Бер мәртәбә динен, иманын сата икән бәндә, аның белән теләсә нишләп була. Ленин моны яхшы аңлый, шуңа күрә, әнә син бая әйткәнчә, яшьләргә каныкты да ул. Ил буенча яшьләр төркемнәре төзелә. Гәҗитләрдән укып барам — уңышка ирешәләр дә булса кирәк. Кабат әйтәм, Әхмәтсафа дөрес аңларга тиеш,— ул түр якта утырган егеткә төбәп сүзен дәвам итте,— гыйлемлелек бер нәрсә, әмма иманга хилафлык китерәсең икән, моны бер нәрсә белән дә аклап булмаячак. Дәүләтъяр нәселе бу якларга Нократ Иделе тирәсендә көн иткән җирләреннән кубарылып, чукындырудан качып килеп чыккан. Өлкәннәрдән калган хәбәрләргә караганда, борынгы бабаларыбызның берсе Казан артындагы Арча төбәгендә сәет булган. Сәет инде ул — димәк, пәйгамбәрләребез Мөхәммәд нәселеннән дигән сүз. Менә без нинди нәсел! — Гомәр абзыйның тавышында горурлык чаткылары бар иде.

— Син әйтә башлаган идең, Гомәр абзый, шул нәрсә күңелдән китми генә бит: ярлы-ябагайга таянып илне алга алып барып буламы, җә?

— Дөрес, туганым. Ярлы-ябагай булганны әрәм итәргә, бирсәң алып, бирмәсәң талап көн күрергә маһир. Гәҗитләр язганны укып, шаклар катып утырам инде. Борын төбендә язгы чәчү. Үткән ел, үзең беләсең, елы әйбәт килсә дә, безнең яклардан зур яулар үтеп, игеннәрне басуы-басуы белән юкка чыгардылар. Көлтәгә куйган игенне ут төртеп харап итеп бетерделәр, адәм имгәкләре. Кызыллары — акларга калмасын дип, аклары — кызыллар кулына эләкмәсен дип тырыштылар. Инде шул ут-давылдан калган икмәк өлешен дә тартып алалар хәлле крестьяннан. Продразверстка дип атала ул хикмәт. Инде ике ел крестьянның башын күтәрергә ирек бирмиләр шул хөрәсәннәр. Кеше талап көн күрергә маташкан бәндәләрне хөрәсән дими, ни дисең?..

— Прод...продра...

— Продразверстка,— дип кабатлады Гомәр агай.

— Тел сындырмалы, иеме?.. Хәлле кеше бөлсә, ярлыябагай да ачтан интегәчәк бит,— диде Мостафа, үз-үзенә ачыш ясагандай.— Хөкүмәт шуны белмиме?

— Бәлки, beләдер дә... Бәлки, акыллары җитмидер. Татарның ярарга тырыша торган яман гадәте бар.

— Ходай сакласын инде,— дип җөпләп куйды аны Мостафа.— Бу хөкүмәтнең кыланганнарын карап торам-торам да, йөрәкләр жу итеп китә. Өметле түгел сыман... Бер дә эчкә җылы йөгерми, Гомәр абзый.

— Сәүдәгәрләребез кайсы кая таралып бетте,— диде Гомәр абзый һәм түр яктан бер китап алып чыкты.— «Торгово-промышленная Россия» дип аталган менә бу китапка сәүдәгәр буларак мине дә теркәп куйганнар иде,— диде ул, нәкъ баягыча ачы көлемсерәп. Китапның каурый кыстырып куйган битен ачып, кычкырып укып күрсәтте.— Давлетъяров Гумер, дигән, Оренбургский уезд, дигән, Сәет бистәсеннән дип күрсәтелгән. 1899 елда Петербурда финанс министры хәер-фатихасы буенча дөнья күргән китап... Менә безнең сыман уртакул сәүдәгәрләрне дә бөртекләп җыйдылар элек... Кая хәзер безнең сәүдә йортлары? Тартып алдылар...— Гомәр абзыйның күзеннән яшь атылып чыкты.— Мин халыкка аң-мәгърифәт бирәм дип, күпме китап, гәҗит тараттым бушка. Һәр кибетемдә китап сата торган бүлекләр оештырдым. Минем әшнәләрем Гаяз хәзрәт Исхаков, Галимҗан Ибраһимов, Рәмиевлар иде. Кая ул вакытлар? Ни өчен шәкертләр хәзер бер китап алырга тилмереп йөри? Мин инде карт кеше, яшьләр нишләр? Кая менә бу китапта күрсәтелгән шөһрәтле Хөсәеновлар, Кильдияновлар, Динмөхәммәтовлар?.. Гобәйдуллиннар, Әҗемнекеләр кая китеп беттеләр? Кая аларның мал-мөлкәтләре? Рәмиләр алтын приискаларын хөкүмәткә биреп котылмакчылар иде, ни булып бетте? Хәзер Дәрдемәнд — атаклы миллионер, шагыйрь кая барып бәрелергә белми каңгырып йөри...

Гомәр агай сызлаулы тавыш белән шигырь укый башлады:

Һай, гомерләр... үтте китте...
Кая китте ул заман!
Кайда ул шәп һае-һулар!
Гөфтегүләр бар иде...

Ул яшьле күзләрен сөртте һәм, Әхмәтсафага карый төшеп, аңлатма да бирәсе итте:

— Менә бит, «һае-һулы гөфтегүләр бар иде» ди Закир Рәмиев-Дәрдемәнд хәзрәтләре. Шау-гөр килеп әңгәмәләр кора идек, ди. Хәзер сөйләшү ничек? Килеп кергәнеңә кайчан, Мостафа туган, зарланудан бушаган юк.

Мостафа эндәшмәде.

— Юк, туган, бу юл белән барып булмый,— диде Гомәр агай әрнеп.— Малны талап, әрәм-шәрәм итеп түгел, булганны саклап, халыкны тагын да мөлкәтлерәк, маялырак итеп

кенә ил алга бара ала. Шулай булмаса, синең сүзең дөрес — өмет юк...

Мостафа, Гомәр агайның әрнүле сүзләреннән соң, гел бетереште кебек. Йөрәгенең иң түрендә ярсулы хисләр кайный, җаны бәргәләнә. Гомәр абзыйсы да авыр уйлардан ялгызы кыйналып яшәп ята икән бит. Ни дип юатырга аны? Юк шул, юатыр, тынычландырыр сүз таба алмый ул.

Әхмәтсафа өлкәннәрнең сөйләшүләрен, бигрәк тә Гомәр абзыйның рәнҗүдән кызарып-бүртенеп хәзерге хөкүмәтне тиргәвен килештермичә, аның сүзләренә үзенчә бәя биреп утырды. Күп сүзләрнең үзенә карата әйтелгәнен, аның хәтеренә салып куярга омтылып сөйләнгәнен дә аңлый иде ул. Мифтах хәлфәнең шәкертләренең җавабыннан риза булмаган чакларда шаяртып әйтә торган сүзе бар: «Дөрес!..— ди ул кистереп. Бертыннан соң өстәп куя: — Ләкин алай түгел ул...»

Өлкәннәр һич кенә дә хәзерге зур үзгәрешләрнең асылын аңлый алмый һәм аңлый алмаячак та дип уйлый иде ул. Каникулга таралыр алдыннан институтка губкомнан вәкил килеп: «Әле революция яңа башлана!» — дип чыгыш ясаган иде. Аның сүзләре аңлаешлы иде, ичмаса. Бөтен кеше дә тигез, бәхетле яши икән, моннан кемгә зыян?.. Йә әйтегез, начар сүзләрме бу? Бөтендөнья эшчеләре, бүгенге әңгәмәдә еш яңгыраган ярлы-ябагайлар көрәшкә кушылып бетсәме?! Аңнардан вак крестьян психологиясен куып чыгармый торып, алгарышка өлгәшеп булмаячак. Яңа инкыйлаб кирәк! Аң, җан инкыйлабы. Шул чакта гына илдә яңа тәртипләр урнаштырып булачак. Яңалыкка һәрвакыт каршы чыгучы табыла. Әле дошманнарны тар-мар итеп, бөтен дөньяда пролетариат диктатурасы урнаштырасы бар. Институтка партия-совет курсларында дәрес бирүче укытучылар да килеп йөриләр. Бигрәк тә Заһид Шәркый кебек ихластан яңа тормыш өчен янып йөрүчеләрнең чыгышлары йөрәккә сары май булып ята. Яңача яшәүнең никадәр матур, шатлыклы һәм хөр булачагы хакында сөйләп, институт шәкертләренең күңелләрен җилкендереп китәләр алар.

Гомәр агай белән әткәсе Әхмәтсафаны тора салып инкыйлабчы булып китте дип уйлыйлар икән — ялгышалар. Иске тормышның бар «ләззәтен», «рәхәтен» үз җилкәсендә татымадымы ул?! Янгыннан соң өйсез калып, Тайфә карчыкның тавык кетәге кадәр йортында иза чигүләрен исенә төшереп, йөрәгенә кан сава. Әтисе: «Дөньяның тоткасы — сәүдә эше!» — дип йөрде моңарчы. Сәүдә гөрләп бармаса да, бөтенләй гаиләне ким-хур итмәде ул. Ил-көннең тынычлыгы киткән иде, сәүдә эшенең дә көе китте дә куйды. Димәк, бу юл ышанычсыз булган. Җирләре аз, булган кадәре-

сеннән дә уңыш җыеп алып буламы, юкмы — елның ничек килүенә карый. Өлкәннәр моны Ходай кулында, диләр. Аларның гаиләсе авыр тормышта яши хәзер. Кемгә дә ярдәм сорап барышлы түгел: элекке сәүдәгәргә ярдәм кулын сузам дип торучы булмаячак. Дөрес яшәмәгән әткәсе. Кәсепчелек итүнең дөмбере менә кайчан килеп чыкты. Бүгенге вазгыятьтә Гомәр абзыйның сүзе түгел, ә Заһид Шәркыйның бәхетле киләчәк хакында сөйләгәннәре өскә чыга иде. Киләчәк хакындагы сүзләр егетне җилкендерә, аңа канатлар өсти. Көнлекче булып та, казакъ якларыннан тире-яры җыеп, сәүдәгәр исеме күтәреп йөреп тә мантып булмаячак. Илдәге һәр нәрсәгә хуҗа булып алсак кына өметле һәм ышанычлы юлга чыгарбыз. Ул чагында инде ярты елга бер күргән туганың белән сөйләшергә сүз тапмый көне буе зарланып, өметсезлек сазлыгына батып, җәфа чигеп утыру булмас. Бик тә өметле сыман тоела аңа киләчәк. Алда аларны якты еллар көтә! Шуларны белә торып, ничек күңелсезләнеп утырасың ди?! Ул татлы хисләр иркенә бирелеп, киләчәк хакында хыялга чумды...

Кыш ахырларында «мәдрәсә», «Хөсәения» сүзләре студентлар теленнән бөтенләй төшеп калды дисәк тә ярый. Шактый еллар милләткә хезмәт итте Хөсәеновлар. Шөһрәтле иделәр. Үз көчләре, үз маллары хисабына тау ташыннан шулкадәрле төзек һәм күркәм мәдрәсә салдырып куйдылар. Ташны ташка, җеген җеккә китереп, үтә дә осталык белән татар-мөселманнар төзегән бу өч катлы бина каланың күрке иде. Гражданнар сугышы чорында байларның мал-мөлкәте, шул исәптән «Хөсәения» дә тартып алынды. Байлар мәдрәсәне үз теләкләре белән сәвиткә тапшырганнар дигән сүзләр дә йөрде. Бирерсең, бирмичә кая барасың. Дөрес, ләкин алай түгел ул... Мәдрәсә бинасы губерна милке итеп игълан ителгәч, башта Көнчыгыш халык мәгарифе институты итеп үзгәртелде. Оренбур Казахстан АССРның башкаласы итеп игълан ителеп, берникадәр вакыт үткәннән соң, институтны вак халыклар өчен мәгариф-мәгърифәт кадрлары әзерләүче төрле бүлекләргә таркаттылар. Бер үк бина, түбә астында казах халык мәгариф институты (КИНО), татар халык мәгариф институты (ТИНО), башкорт халык мәгариф институты (БИНО) һәм башка институтлар барлыкка килде.

Татар гомер бакый сабак алучы җан иясен «шәкерт» дип атап йөртте. Бусы да яңа хөкүмәткә ярап бетмәде. Студент! Килеп чыгышы, тамыры кайдандыр бу сүзнең, анысын уйлап торыш юк, тиз арада шәкертләр яңа атамага ияләнергә тиеш булдылар.

Февраль ахырлары... Бу якларда җәй эссе булган кебек, кыш та суык килә. Чатнама суыклар башланды. Мәдрәсәне тиешенчә җылыта алмыйлар, шуңа күрә студентлар хәтта йоклаганда да өсләрендәге бишмәтләрен салмыйлар. Ай буе юынмыйча яшәделәр дисәң дә ярый. Төс-кыяфәтләр мактанырлык түгел. Студентлар әкренләп бер-берсенә охшап баралар — хөртиләнә эшләр, хөртиләнә... Хөкүмәт төрледән-төрле шигарь уйлап табарга оста булса да, хәерчелеккә тәгәрәгән илне бөтәйтерлек хәле юк иде. Аның караве көн саен җыелыш яки кичә оештырыла. Анда ике сүзнең берендә «хәрби коммунизм», «яңа икътисади сәясәт» дигән серле һәм ымсындыргыч гыйбарәләр еш яңгырый. Андый чакларда Саттар Әхмәтсафаның колагына пышылдый:

— Дөрес... ләкин алай түгел ул...

Халык коточкыч тизлек белән хәерчеләнә. Элекке бае, урта хәллесе эшсез-җирсез көн иткән сукбай хәленә төшteләр. Барысы да тигез хәзер — барысы да совит хөкүмәте үзенә бердәнбер таяныч итеп күргән ярлы-ябагай катлавына күчеп бетеп бара иде. Болай булса, дөнья революциясе дә ерак йөрмәс.

...Салкын бүлмәдә Әхмәтсафа Иләк каласыннан килгән Зиннәт Габдрәшитов исемле студентка хисаптан дәрес хәзерләргә булыша иде. Зиннәт укуга ни сәбәптәндер соңга калып килде. Җитмәсә, хисап кебек төп фәннән белеме чамалы икәнлеген белә торып, аны хәзерлек курсының (шулай ук яңа сүз!) икенче сыйныфына, ягъни Әхмәтсафалар укыган сыйныфка кертеп утырттылар. Егет үзе тырыш болай. Башкалар эчләренә төшкән суыкны куарга теләп, бераз ял итеп, шаярып, күңел ачып алган чакларда да, ул баш күтәрми дәрес хәзерләп утыра. Бу хәлне иң беренче Мәҗит килештермәде. Иңсәсенә салган иске кайры туны якасына төрткән борынын кинәт өскә чөеп, тәкәббер тавыш белән Зиннәткә дәште:

— Туган, күңелеңә авыр алма, институт, диләр моны, шәкертләр бет симертеп яткан сала мәдрәсәсе түгел. Ышы гапгади мәсьәләне дә чишә алмагач, нинди студент ди инде син? Булмый, булмый!..— Янәшәсенә озын чәчләре маңгаена сибелгән, күзен чепиләндереп, иренен кысып, теш арасыннан сөйләшергә яратучы Фатыйх Сәгыйтов килеп басуын күреп, тагын да зәһәрләнә.— Казна ашын ник ышындый наданнарга әрәм итәләр микән? — диде ул һәм түшәмгә элеп куйган борынын кабат тун якасына кадап куйды. Кемкем, әмма Мәҗитнең — хисаптан үз башы белән бер мәсьәлә чишә алмаган кешенең — Зиннәттән көләргә маташуы үзе бер көлке булганга, бүлмәдәгеләр аңа күтәрелеп тә карамадылар.

Фатыйх Сәгыйтов та аңа тиз генә җавап бирмәде. Әгәр янәшәдә башкалар күренмәсә, акыл сатып, гәп куертып торуны урынсызга саный ул. Үзен тыңлаучылар булмаса, кем дәшсә дә, җавап кайтарып тормастан, каты адымнар белән йә бүлмәдән үк чыгып китә, йә ятагына барып ава. Әгәр инде тыңлаучы табылса, шуны гына көтеп торган диярсең, үт суы кушылган бер-ике җөмлә атмый калмый. Бу юлы дәшми калу мөмкин түгел. Бүлмә тулы кеше...

— Татарны электән надан муллалар харап итте, хәзер аларга алмашка надан Зиннәтләрне әзерләп чыгарабыз...— «Зиннәтләр» дигән арада утлы карашы Әхмәтсафаны, Сәгыйтьне, шигырь язып мәшәләнүче Габдулла Амантайны, Саттарны, Әптерине, кыскасы — бүлмәдәге һәркемне өтеп чыгарга өлгерде. Бүлмәдәшләрен җай чыккан саен «мие кипкән тиле, надан» дип үртәүдән тәм тапкан Фатыйх Сәгыйтов, укуга омтылышы көчле булган Тозиле егете Зиннәтнең җанына кагылып китә алуына куанып, ләззәтле мизгелләр кичерә иде.

Үзен наданлыкта, булдыксызлыкта гаепләгәндә, Зиннәт колагына кадәр кызара. Кичке ашка да бармый, башын дәреслектән күтәрми утыра иде.

Беркөнне Сәгыйтовның чираттагы «мунчасыннан» соң, алдында яткан хисап дәреслегенә сеңеп бетәрдәй булып газап кичерүче Зиннәт янына Әхмәтсафа килеп утырды. Зиннәтнең туя ашамаудан яңаклары эчкә суырылып кергән. Керфекләренә яшь бөртеге эленгән... Янына Әхмәтсафаның — уен-көлкегә һәвәс Каргалы егетенең килеп утыруына да артык әһәмият бирмәде. Хәтта бөрешеп калган кебек тоелды: Мәҗит белән Фатыйхка иш табылды дип уйлады булса кирәк. Китабын бер читкә ташлап, урыныннан кузгалып китмәкче иде, нигәдер тыелып калды.

Әхмәтсафа, Зиннәтне тынычландырырга тырышып, ипле генә сүз башлады:

— Дустым, инде башка фәннәрдән безне куып җитеп киләсең, афәрин. Хисапка килгәндә... без болай итик...— Әхмәтсафа егеткә җан иңә башлавын тоеп, ышанычлы тавыш белән дәвам итте.— Мин сиңа хисаптан дәрес эшләргә булышам, ә син миңа урыс теленнән ярдәм итәрсең.

Зиннәтнең йөзе балкып китте. Якты күзләре белән Әхмәтсафага күтәрелеп карады. Ирен читләрендә соңгы вакытларда сирәк күренгән елмаю пәйда булды. Базык гәүдәле, киң күкрәкле зәңгәр күзле бу егетнең чын күңелдән аңа ярдәм кулы сузарга җыенуын аңлап алган Зиннәт, үзүзен белештермичә, сыйныфташын кочаклап алды.

— Риза, димәк?..— дип, егетне читкә этәрә төште Әхмәтсафа һәм аңа кулын сузды. Зиннәтнең суыктан кыза-

ра төшкән кечкенә кулы Әхмәтсафаның зур учына кереп кенә чумды.

— Мин синнән чын урыс ясыйм! — дип, шапырынып җибәргәнен дә сизми калды Зиннәт. — Мин бит гел урыс малайлары белән уйнап үстем. Шөкер, урысчам сынатмады монда.

Зиннәт белән шулай тиз аңлаша алулары Әхмәтсафаның күңеленә хуш килде. Фатыйх ягына караш ташлады. Тегесе ятагыннан күтәрелә төшеп, бу ике егетнең сөйләшүенә колак салып тора иде. Моны күргәч, тавышын күтәрә төшеп, килешүгә нокта куйды:

— Әйдә, Зиннәт, шушы күркә муеннарга күрсәтик әле, кемнең кем икәнен. Берәүләр — тун бете, — ул Мәҗит ягына баш какты, — берәүләр балак бете булганлыкларына куанып йөри бирсеннәр. — Бу сүзләре белән Фатыйхны ятагына кузгалмаслык итеп беркетеп куйды. — Без синең белән кешеләр булып калыйк.

Шундый көннәрнең берсендә алар янына институт директорының сәяси эшләр буенча урынбасары Заһид Шәркый белән Гайшә Мөхәммәдова (ул әдәби кичәләр үткәрү өчен җаваплы студентка) килеп бастылар. Алардан бераз арттарак беренче күрүдә үк егетнең йөрәгенә ут салып өлгергән Заһидә коңгырт күзләрен елтыратып тора.

Керүчеләрне абайлап алгач, Әхмәтсафа урыныннан сикереп торуын сизми дә калды. Бу кадәр каударлануының сәбәпчесе, әлбәттә, Заһидә иде. Ул башкалардан битәр Заһидәгә дәшкән кебек сөйләнгән булды:

— Дәрес әзерлибез, — диде ул. Каушавын яшерергә тырышса да, барып чыкмады.

Гайшә, ерылып китәргә генә торган авызын бар хутына җәеп, егетне үчекләп алды:

— Ә без тагын кузна уйныйсыз дип торабыз... — Заһид Шәркыйга аңлатасы итте. — Безнең Әхмәтсафа круглый отличнога гына укый. Әле тагын бер яктан ачылды — бер дигән мөгаллим икән үзе — Зиннәттән математик ясый инде. Кайчан гына койрыкта сөйрәлгән Зиннәт, безне ырыперып дигәндәй алга үрмәкли, әйеме, Заһидә?!

Заһидә авыз ачып сүз әйтергә өлгермәде, Заһид Шәркый кулын Әхмәтсафаның иңсәсенә салды:

— Афәрин, егет икәнсең. Шулай бер-берегезгә ярдәм итеп укуыгызга чын күңелдән куанам, — диде һәм, рөхсәт сорап тормастан, Зиннәтнең дәфтәрен алып актара башлады. — Катлаулы нәрсәләр бар монда... — дип, ул янә бер мәртәбә Әхмәтсафаның эшен хуплавын белдерде. — Афәрин, иптәш Дәүләтъяров, афәрин.

«Иптәш» дип дәшү шулкадәрле ят һәм шул ук вакытта

кешене үсендереп җибәрә икән, Әхмәтсафа бер баскыч югары күтәрелгәндәй булды. Биеккә чөелгән арада күз чите белән генә Заһидәгә дә караш ташларга өлгерде. Заһидә исә күзен аска төбәп дәшми басып торуын белә иде.

Заһид Шәркыйның Әхмәтсафаны мактап алуы, озын колак Мәҗитнең кай җиренәдер ярамады.

— Кем кемне өйрәтәдер бит әле,— диде, саңгырау тавыш белән.— Зиннәт үзе башлы егет. Ярдәм итәм дип, маңгаеңны идәнгә бәрсәң дә булмый ул. Ышы бу дөньяда үзенә файдасы булмаса, кеше бармагын да селкетми. Зиннәт Әхмәтсафаны урысчага өйрәтә. Нишләп анысын искә алмыйсыз? — диде ул, борынын лыш-лыш тартып.

— Дәүләтъяров бу хакта үзе әйтергә тиеш иде дә, маладушничить итә...— дип сүзгә кушылды Фатыйх Сәгыйтов.— Ә сез аны иптәш дисез...— диде ул, мыскыллы тавыш белән.

Келт итеп Мифтах хәлфә искә төште. «Иптәш» сүзен өнәми иде ул.

«Моны юридик белеме булган Ленин дигән бәндә куллануга керткән. «Иптәш» сүзен хөкем-мәхкәмә эшләрендә йөрүчеләр, бигрәк тә прокурор дигәннәре яратып куллана. Ленин шул прокурор булырга хыялланып та, була алмагач, бу сүз белән фиркадәшләрен атап йөртә башлый. Прокурор-гаепләүче. «Иптәш» сүзен яраткан икән, димәк ки, Ленин да башкалардан гаеп эзләп йөрүче инде»,— дигән иде ул бервакыт.

Көтмәгәндә Фатыйхның аңа бәйләнүеннән аптырап калган иде Әхмәтсафа.

Бәхеткә, сүзгә Саттар кушылды. Саттар Ишбулдин институтта иң көчле егетләрнең берсе. Яхшы укый, уку эшләре комиссиясенең актив әгъзасы иде.

— Нигә үзегез башта ярдәмгә килмәдегез Зиннәткә?! — диде ул кайнарланып. Мәҗит белән Фатыйх шундук тынып калдылар.— Әхмәтсафа, гомумән, институтта беренче булып, артта калган сыйныфташларга ярдәм эше оештыруның инициаторы булды. Син, Мәҗит, үзең урыс теленнән, хисаптан чеп-чи надан.— «Надан» сүзен болай маңгаена чәпеп әйткәч, Мәҗитнең күзе урыныннан кубып, колак артына тәгәрәп, кире оясына кайтып утыра алмый азапланды.— Зиннәттән көлеп йөргәнче, аннан үзеңә өстәмә дәрес бирүен үтенсәң яхшырак булыр иде. Синең аркада сыйныфыгыз «ташбака» исеме алды.

Мәҗит, Саттарның һөҗүмен кире каккандай, сыңар кулын канат сыман җилпеп алды да ишеккә ташланды. Аның:

— Харап, Каргалыда икән укымышлылар,— дип мыгырданып үткәнен Заһид Шәркый көлемсерәп карап калды.

Заһид Шәркый патша армиясендә хезмәт иткән солдат.

Гражданнар сугышында да катнашкан. Өстенә һәрвакыт шинель киеп йөри, аягында, кайсы сугыштан калганы билгесез, башы тишелгән, шулай да яхшы итеп каралтылган ботинка. Нәзек, озын буйлы әлеге мөгаллим барлык студентларның да яраткан укытучысы иде. Аның төп вазифасы — институтта сәяси-агарту эшләрен оештыру булгач, дәресләрдән соң үткәрелә торган барлык чаралар өчен дә турыдан-туры җавап бирә иде.

Көтмәгәндә купкан бәхәс шулай көтмәгәндә басылып та калды. Заһид монда керүләренең сәбәбен аңлатты:

— Сезнең яраткан шагыйрегез Такташ Оренбурдан китәргә җыена. Афзал Таһиров белән сөйләштек тә институтта шагыйрьнең саубуллашу кичәсен үткәрергә булдык. Кызлар инде кичәнең сызмасын да төзеп куйганнар. Аның белән танышып чыктым, күңелле генә үтәр сыман дигән фикер туды миндә.— Ул, үгезне мөгезеннән дигәндәй, Әхмәтсафа янындагы буш бүкәнгә килеп утырды да йомышын әйтеп салды.— Кичәнең ярты уңышы — алып баручыларда. Сиңа, Әхмәтсафа, шушы эшне тапшырабыз. Заһидә белән икегез ерып чыгарсыз дип уйлаштык...

Заһиданең күзендә яшь чагылып китте, ул, артка борылып, борын тирәләрен җыештырып алды. Гайшә кызны чынчынлап шелтәләп тә ташлады:

— Җитте, Заһидә! Ничә тапкыр әйтергә кирәк сиңа?! Такташ китә дип бөтен институт кызлары яшь түгә башласа — туфан калкыр. Кичәне көймәләргә төялеп, күз яшьләре диңгезендә үткәрергә туры киләчәк. Такташ — әйбәт шагыйрь. Аны шуның өчен хөрмәт итәбез, яратабыз. Бер син генә түгел, барыбыз да! — дип басым ясап әйтте ул. Аннан шаяртуга күчте.— Безнең егетләребез кимме шаирь Такташтан? — Шул арада Әхмәтсафага күз кысып алырга өлгерде.— Әйеме, Әхмәтсафа?!

Заһиданең Такташ өчен болай үрсәләнүен күреп, егетнең йөрәге кысылып куйды. Шулай да, үз-үзен җиңеп, Заһид Шәркыйдан кичәнең сызмасын аңлатуын үтенде. Аңышкач, көттереп кенә:

— Нәрсә әйтергә дә белгән юк...— диде, кичәне тиешенчә алып барып чыгуына ышанып җитмичә.— Минем әле мондый зур сәхнәгә чыкканым, кичәләр алып барганым юк. Куркыта...

— Кара әле моны! Сәхнәдән куркам, ди. Кеше ышандырырсың. Нәмә сөйләп торырга — чын артист инде ул! — дип, Гайшә егетнең салпы ягына салам кыстырды.— Такташның шигырьләрен ятлап, декламация сөйләп тә җибәрсә...

— Дөрес,— дип, Гайшәне куәтләде Заһид Шәркый.— Аннан гимнастик күнегүләр ясар дип тә ышанып торабыз.

Афзал агай синең турникта кыланмышларыңны шаккатып сөйли әнә.

Студентларны Һади Такташ дигән мишәр егете белән нәкъ менә Афзал Таһиров — физкультура укытучысы таныштырды да инде. Егетнең бүгенге татар дөньясында иң көчле, сокландыргыч шагыйрь икәнлеген дә кызып-кызып ул аңлатты. Афзал абыйсы аеруча Әхмәтсафаны үз итә иде. Аның дөньяга карашын үзгәрткән, укуына зур йогынты ясаган кешеләрнең берсе — Афзал Таһиров иде.

Афзал Таһиров — утыз яшьне үтеп баручы, һәр нәрсәгә сәяси күзлектән карарга һәвәс кеше иде. Җиңел адымнар белән барышыннан ук ниндидер ашкыну, тыелгысыз дәрт сизелә. Студентларны бөтенләй шаккатырганы — ул кышкы чатнама суыкларда да яланбаш йөри. Озын чәчле, ыспай гәүдәле, хәрбиләрчә шакаеп — гәүдәсен төп-төз тотып йөрергә ярата. Физик яктан да көчле укытучы иде. Аның янәшәсендә Такташ малай гына сыман. Яшь аермалары шактый булса да, күрәсең, бик дуслар, еш кына институтка да бергәләп киләләр. Аларны тагын якынайткан нәрсә — икесе дә «Юксыллар сүзе» дигән газетада эшлиләр. Афзал Таһиров — мөхәррир, ә Такташ шул ук газетада җаваплы сәркатип. Әхмәтсафа бу эшләрнең кайсы ни дәрәҗәдә җаваплы икәнлеген аерып әйтә алмаса да, кемнең баш, кемнең түш икәнен яхшы белә.

Физкультура дәресләре махсус җиһазландырылган бүлмәдә үтә. Афзал абыйның горурлыгы иде ул. Мактана төшеп кабатларга ярата:

— Мондый бүлмә Оренбурда гына түгел, якын-тирә шәһәрләрдә дә юк әле. Снарядларны,— шушы сүзне ул аеруча басым ясап әйтә,— бөтен Рәсәй буйлап җыйдым. Үз кулларым белән көйләдем, беркеттем. Көчем әрәм китәр микән, дип курыккан идем, шөкер, үземә эшләргә насыйп булды.— Әлеге сүзләрне Такташка да әйткән иде. Аңлатма биреп китәсе итте.— Берара губерна мәгариф бүлеген җитәкләргә туры килде миңа. Нургали Надиев, ул чагында мәдрәсә директоры, көн саен яныма килә дә физкультура бүлмәсе ясарга хыяллануы хакында сөйли. Тел төбе аңлашыла — мондый зур эшне башкарып чыгу өчен таяныч кирәк. Мин ярдәм итәргә булдым... 

Ахыргача үземә ерып чыгарга да туры килде. Шуңа күрә, газетада эшләсәм дә, физкультура дәресен кемгәдер бирәсем килмәде. Бигрәк тә, менә шундый егетләр бар чакта,— дип, җай чыкса, Әхмәтсафаны үз янына чакырып китерә.

— Дәүләтъяров, әйдә әле тәннәреңне язып ал. Күрсәт һөнәреңне! — дип әмер бирә егеткә.

Әхмәтсафага шул гына кирәк тә. Көне буе башка дәресләргә йөрми, шушы бүлмәдә бикләп яткырсалар да риза.

Иң элек аякларын өскә күтәреп, кулы белән йөреп китә. «Эһ» тә итми бүлмә буйлап бер әйләнеш ясап чыга. Аннан мәтәлчек атып, тегеләрнең исләрен ала. Берсендә һөнәрен Такташка да күрсәтергә туры килде. Егетнең бу кадәр кылануына Такташның күңеле булып, килгән саен, Афзал агайдан узып, Әхмәтсафадан гимнастик күнегүләр ясавын үтенә. Үзе читтән карап, бу хәлгә хәйраннар калып, дөньясын оныта, кулларын уып, ара-тирә сөйләнеп ала:

— Выт бит әй! Сөяге юк инде моның, сеңердән генә тора бу...

Такташның юк кына нәрсәгә дә исе китүенә, чын күңелдән сөенә алуына Таһиров үзе дә куанып, Әхмәтсафаны дәртләндергәннән-дәртләндерә:

— Әй афәрин... Әй булдыра... «Күпер» ясап та күрсәт... Сальто дигәнен дә ясап җибәрсәң. Һо-оп... Менә мондый егетләр бар бездә! — ди ул ахырда.

Әхмәтсафаның арырга исәбе күренми. Ял итеп тормыйча, әнә сыйныфташлары янына китеп, аларга күнегүләр ясарга булыша. Монысы да Таһировның күңеленә хуш килә.

— Дәрескә килеп җитә алмый тоткарлансам, шушы егеткә ышаныч. Тумыштан спортчы бу егет. Әле бокс, йодрык сугышы белән җенләнде. Институтта түгәрәк ачып йөри. Кулларын күр аның! Крестьян малае бит — көрәк кадәр бер-бер кулы. Яшьләр үсә, — ди ул, хискә бирелеп.— Без яшьлекне патша окопларында исраф иттек, революция ялкынында яндырдык...

Такташ аны тынычландырырга ашыга:

— Алай димә, Афзал әзи. Кая әле сиңа картаю! Картлык — карт аю, синнән ерак йөри әле. Җәһәннәмгә олаксын сиңа киләсе картлык,— ди ул көлеп.

Һади бер-ике кичәдә Әхмәтсафаның декламация сөйләвен дә ишетеп сокланды. Студент егет үзе артык салмак холыклы булгангамы, алар ныклап танышып-дуслашып китә алмадылар. Шулай да Такташ аны үз итеп, якын итеп йөри, очрашканнарда дә хәл-әхвәл сораша, укуы белән кызыксынмый китми иде. Саубуллашу кичәсен Әхмәтсафаның алып баруын Афзал Таһировтан үзе үтенгән икән. Һәм Заһид Шәркый бу үтенечне егетнең үзенә дә җиткерде менә.

Кичәгә бер атналап кына вакыт калып бара. Озакка сузар чара юк. Такташ үзе сорагач, Әхмәтсафа каршы килү хакында уйламады да. Баштагы кыенсынып торуны онытып, шунда ук сызманы дикъкать белән карап чыктылар. Әхмәтсафа тәкъдиме белән студентлар оркестры чыгышы да программага кертелде. Ул ике халык көе уйнарга тиеш булды. Оркестрга кушылып җырларлык җырчылары да бар аларның. Берничә җыр яңгыраячак. Аннан сүз шагыйрьнең

үзенә бирелеп, әле «десерт» өчен генә берничә шигырен укып, сәхнәдән төшеп торачак. Төрле номерлар күрсәтеләчәк, соңыннан инде сәхнә тулысы белән шагыйрь карамагында. Тамашачылар хушланганчы шигырьләрен укысын...

...Алдагы көннәрдә янып-пешеп репетицияләр үткәргәндә, Әхмәтсафа үз янында Заһидә булуын тоеп, аеруча илһамланып йөрде. Кыз үзе дә егеткә битараф түгел сыман, тик нииндидер көч аның хисләрен богаулап тота. Әхмәтсафа ятышсыз егет түгел, кайсы гына кызга тартылса да, моны теге кызлар язмыш бүләге дип кабул итәр иде, һичшиксез, сөенә-сөенә егеткә дуслык кулын сузар иде. Бу хакта аңа Гайшә инде ун мәртәбә әйтте. «Әгәр күңелемдә башка егет булмаса, ике дә уйламый шушы Әхмәтсафаның башын әйләндерер идем», — дип тә ычкындырганы бар. Заһидә авыр сулап куйды ул чакта. Менә бит ничек, Гайшәнең күңеле күңел дә, Заһидәнекендә таш микәнни?.. Күңел түрендә балкып янган йолдыз — зәңгәр күзле, шаян табигатьле мишәр баласы — Такташ булуын белмиме ахирәте?! Белә... Имеш, шагыйрьгә, буй җитмәслек йолдызга үрелеп, кысыр хәсрәттән саргаеп кипкәнче, әнә — янында бәхет кошың, шуны әләктер, дип әйтәсе килүе аның. Их, күңелнең җилкенүен шулай салкын акыл ихтыярына буйсындырып, яңадан мәңге кабынмаслык итеп сүрелдереп булса иде дә... Кызның уй-теләкләрен аңлаучы юк. Аннан көләләр генә. Хәер, нигә анда әллә кемнәр әллә ни сөйләми — тел сөяксез, мәхәббәт утында янган йөрәкнең берсендә дә эше юк — януы яну. Көтмәгәндә дөрләп кабынган күңел утын сүндереп булмый икән. Заһидәнең уе — гел Такташ тирәсендә бөтерелә. Шушы егет белән саташып, хыялланып бетә бугай инде. Төннәрен Такташ дип мендәрен кысып кочаклап ята. Саташулы халәттә шыбыр тиргә батып уяна, янәшәсендә әле генә үзенә сыенып яткан «мәхәббәт төенчегенең» кинәт юкка чыгуына риза булмаган хыялы чынбарлык белән шактый озак тарткалаша әле. Мәхәббәттән иләсләнгән җан эчен җыя алмаган бәбкә белән бер икән ул. Бүген көндез баскычка абынып егылуы да Такташ аркасында. Нәкъ шушы мәлдә хыялында Һадиның тузган чәченә кунган җепшек кар бөртекләрен кагарга дип сак кына үрелгән иде. Тегесе зәңгәр күзләрен нурландырып, дәшми генә елмаеп тора. Хәерсезгә каршы, әлеге хыялый мизгел кызның күңеленә баскычтан күтәрелеп барган чагында килеп керде шул. Һәм... Заһидәнең бөтен сыйныф алдында мәтәлеп китүе белән тәмамланды. Их син сөю, әх-ти мәхәббәт! Җавапсыз мәхәббәттән акылдан язган кешеләр хакында да ишеткәне бар кызның. Димәк ки, һич арттыру түгел, Заһидәне Ходай шушы сынауга дучар иткән. Ахыры хәерле бетсен.

Репетиция вакытларында Әхмәтсафа белән Заһидә берберсе каршында үзләрен җайсыз-уңайсыз хис иттеләр. Әйтерсең кызның егет алдындамы, әллә егетнең кыз алдында ниндидер гаебе бар. Һич кенә ачылып китә алмыйлар — сөйләгән сүзләре, кыланмышлары табигый килеп чыкмый. Моны күреп торган Гайшә бер үртәлсә, мәсьәләнең төбен аңлаудан ерак булган Заһид Шәркый тәмам гаҗизгә кала иде.

...Кичә көне килеп җитте. Ашханә (мондый тамаша-кичәләр беренче каттагы ашханәдә үтә иде) күз ачып йомганчы студентлар белән шыгрым тулды. Үзенчә җыйнак кына тамаша залы килеп чыкты.

Алгы рәттә, нәкъ Заһидәнең хыялындагыча, кояштай балкып шагыйрь үзе утыра. Ул, Афзал Таһировтан калышмаска теләпме, кыш көне яланбаш, өстенә җиңелчә юка пәлтә киеп йөри. Пәлтә аңа шундый килешә, озын чабулары аяк йөзенә җитә язгангамы, урта буйлы гәүдәсен шактый калку да күрсәтә әле. Шагыйрьгә самимилек, хөрлек төсмере өстәп муенында ак шарф ята. Күзләре исә диңгез зәңгәрлеген хәтерләткән шикелле, һәрхәлдә, мондый чисталыкны йә биек күкләрдән, йә төпсез диңгездән генә табарга була торгандыр. Шагыйрь белән янәшә әдәби түгәрәк җитәкчесе, йөзеннән беркайчан да басынкы елмаю китмәгән Шәриф Камал утыра. Алар белән беррәттән үзен дәрәҗәлерәк тотарга яраткан Афзал Таһиров, институтның башка мөгаллимнәре тезелешеп киткән.

Сул яктан, гадәт буенча, кызлар урын алды. Алар тилгәннән качып, әнкәләренең канат астына борын төртеп маташкан тавык чебиләре кебек, аз санлы мөгаллимәләр тирәсенә сырышалар. Болай карап торуга бик юаш, бичара вә мескен тоела алар. Янәшәдә укытучылар булса, тыныч кына үз алларына оеп, суфиланып утыралар. Тәүфыйк ияләре инде менә. Укытучы-мөгаллимнәр килеп җиткәнче бу чәчбиләр гайбәт сатып, шау-гөр килеп хәлдән тайгандыр дип бер генә кеше дә уйламас. Әгәр чит-ят кеше күреп тормаса, кызлар шактый бәйсез кыланалар, үзләрен үчекләп маташкан егет аламалары белән әрепләшеп алырга да күп сорамыйлар. Һәрхәлдә, аңлашыла торгандыр, шушы рәвешле бер урынга дистәләгән кыз җыелган җирдә үзгә бер тормыш кабынып китә. Егетләр яшәгән бүлмәгә ялгыш кына бер кыз килеп керсә дә, хиссият тиз үзгәреп китүчән бит. Шушы вазгыятьне искә алганда, залда аерым күтәренкелек, аерым бер атмосфера хөкем сөрә. Залда утырган Такташ, Шәриф Камал, Афзал Таһиров сыман әдипләрнең булуы гына моңа сәбәпче дисәк, хакыйкатькә хилафлык китерү булыр иде. Мондый күтәренке рухның сәбәбен ара-тирә сүзгә мавыгып,

онытылып киткәләсәләр дә чыгырдан чыкмаган, мөгаллимәләрнең ачуларын китермәслек итеп сак кына көлешкән-чыркылдашкан кызлардан эзләсәк яхшырак булмас микән?!

Концерт, алдан уйланганча, матур гына башланып китте. Оркестр «Каз канаты» көен уйнап, күңелләрдәге очынуларны баса төште, аннан «Ком бураны» көе уйналып, йөрәкләр тибешен шушы кичәгә кирәк кадәренчә ешлыкка җиткерде. Моңлану — сыктап, сыкрап утыру түгел, җанның вакыты белән татлы, вакыты белән якты, вакыты белән тирән һәм серле халәт кичергән мәле. Оркестр уйнаганда күңел офыклары киңәеп китте, уй-хисләр тагын да җанлырак, нурлырак сыман тоелды, янәшәдә утырган кешеләр дә җанга якынрак, ягымлырак күренгән кебек. Чыгыш арты чыгыш игълан ителеп, чират шагыйрьгә җитте.

Шагыйрь алкышлардан кыенсынган сыман салмак кына урыныннан күтәрелде, тамашачыларга тыйнак кына башын иде. Салам шикелле сары чәчләреннән серле дулкын йөгерде. Килешә, һай килешә иде шагыйрьгә бу рәвеше. Шундук Такташның йөзендә дәрт, тәвәккәллек хасил булды. Ул, күп уйлап тормастан, артык биек булмаган сәхнәгә җиңел генә сикереп менде дә йөзенә үк сибелеп төшкән чәчләрен учы белән артка сыпырып куйды. Юри эшләгән кебек — кулын алуга чәчләр җайсыз гына янә таралып төште. Шагыйрьнең исе дә китмәде. Булгач булсын инде дигәндәй, башын кинәт артка чөеп, тыңлаусыз чәчләрен янә артка ташлады. Ни хикмәт, моңарчы бирешми, каруланып торган чәч көлтәсе, шушы кисәк хәрәкәтне генә көткән икән — баш түбәсенә ипле генә ятты да куйды. Шушы тыңлаусыз чәчләре серле көчкә ия икән: алар белән мәш килеп, булашып алган арада, Такташ залдагы кызларның күңелен янә яулап, аларны «аһ» иттерде дә куйды.

Шагыйрь башта тамашачыларга яхшы таныш «Караңгы төннәрдә», «Җил сөйли» кебек шигырьләрен укыды. Зал мәрткә киткән кебек тын да алмый тыңлап утыра. Тамашачы шигырьдә эреп бетеп барганда, шагыйрь аларны уятып, җиргә төшерәсе итте. Ул сәхнә алдынарак килеп, беренче рәттә утырса да, моңарчы игътибардан читтән кала биргән, шигырьләр тәэсирендә йөзенә алсулык кабынган, шуның нәтиҗәсендә бигрәк тә чибәр күренгән кызга төбәп, берничә сүз әйтүне кирәк тапты:

— Җәмәгать, сөекле тамашачыларым, бүген мин сезнең янга бер кунак кызы алып килдем. Ул — сәяси курсларда белем алучы Гөлсем туташ...

Бөтен зал, әлеге бәхетле туташның йөзен күрә алмаудан гаҗиз калып, алга тартылып куйды. Гөлсем туташ кыю икән, тартынып тормады, битенә кунган көләч елмаюын сүндерми-

чә урыныннан күтәрелде. Залга борыла төшеп, башын җиңелчә иеп алды һәм кире урынына утырды. Сул якка укмашкан кызлар дөньясы каш-керфек тибрәнешләре, йөзләрендә уйнаклап алган сәер чалымнар, кисәк ташланган яндыргыч карашлар белән бу хәлнең гайре табигый булуын, хәтта ки гафу да ителмәскә мөмкин икәнлеген (Без оештырган кичәгә чит кызлар ияртеп киләләрмени, җүләр шагыйрь?! Без үзебез аннан кимме?.. Бу адымың белән безне ничекләр кимсеткәнеңне аңлыйсыңмы син?!) сәхнәдәге шагыйрьгә искәртеп матәшты маташуын, әмма юкка гына тырыштылар, ахрысы. Шагыйрьнең күзенә Гөлсем туташтан башка беркем дә күренми иде, вазгыять институт кызлары ихтыярына буйсынудан үткән, «кулдан ычкынган» иде. Такташ бу үзгәрешләрне бөтенләй сизми, һаман Гөлсем туташка мөкиббән хәлдә торган килеш, кызларны урыннарына кузгалмаслык итеп беркетеп куйган янә ике-өч җөмлә ыргытты:

— Шушы көннәрдә генә «Таң кызы» дигән шиырь яздым.— Ул «шиырь» дип әйтә иде.— Бу шиырьне мин Гөлсем туташка багышладым. Хәзер бу әсәрне сезнең игътибарыгызга тәкъдим итәм.— Такташ Гөлсем туташка карап ягымлы елмайды, дустанә баш иеп алды.

Такташ залда диварларны ватардай булып уйнап алган кара дулкынны тоеп алган иде инде. Үзенең ялгышлык, хата җибәрүен дә чамалады. Шигырьнең Гөлсем туташка багышлануын, бәлки, әйтмәскә дә кирәк булгандыр? Анысы мөмкин эш түгел, нәкъ шушы сүзләрне ишеттерү өчен чакырды бит ул әлеге кичәгә сөйкемле туташны. Шигырьне хәзер түгел, икенче бүлектә, иң ахырдан укырга кирәк булгандыр, бәлкем. Хисләр иркендә иде шул, уйлап җиткерә алмады, бигайбә, кызлар голәмәсе. Һич тә сезгә карата явызлык булып чыгар димәгән иде лә... Сүз — чыпчык түгел, әйтте, авыздан чыгып ычкынды. Кире тотып алып, тел артына салып куеп булмый. Ул, аеруча күтәренкелек һәм җилкенү белән, залда утыручы кызларга карап укый башлады. Шигырьнең уртасына җиткәндә инде аңнар саташа, зиһеннәр менә-менә ычкынырга әзер сыман иде. Шагыйрь исә укый да укый...

Таң кызы, Гөл, ник чыктың да юлларыма,
Бәхет гөлен тотып нечкә кулларыңа,
Маңгаемнан үбеп мине, ник югалдың,
Тагын кире төренеп таң нурларына?

Әсәрнең шигъри көче, шагыйрьнең уку осталыгы һәм үзүзен сәхнәдә тотышы залны тәмам әсир иткән иде. Шушы мизгелләр эчендә, сөйләсәң, кеше ышанмас нәрсә булып алды — кызлар Такташны тулысынча гафу итеп өлгергәннәр иде инде. Чөнки ул шигырьне озын керфекләре арасына үзе

дә кереп югалыр хәлгә җитеп, башын түбән иеп, колакларына кадәр кызарып утырган кунак кызы — Гөлсем туташка түгел, ә нәкъ менә аларга, кызлар утырган якка карап укыды бит. Шигырьнең аларга, фәкать аларга гына төбәп укылуы институтта белем алучы кызларның барсына да көн кебек ачык иде. Шулай булуы алар арасыннан беркемне шикләндерми дә иде. Залга якты дулкын таралды. Теге чакта минут эчендә хәлсезләнеп аяк астына егылган яшьлек хисләре яңадан күтәрелеп, күңел түрендә урын алдылар. Ул гына да түгел, кызларның һәммәсе шагыйрьгә теләктәш иде. Аның саф сөюдән шулкадәрле тилмерүен күз алларына китереп, хисләр ташкынына түзә алмыйча, яшь коеп утыралар иде. Шагыйрь кадәр шагыйрь шулай өзгәләнсен әле... Иң изге хисләрен, мәхәббәтен, язмышын, гомерен шушы таш бәгырьле туташка тапшырып Такташ һич кенә дә дөрес эшләмәгән шул. Бер дә киңәш бирерлек дуслары, иптәшләре юк микәнни соң янында?.. Булса, ни карыйлар, нигә аны дөрес юлга күндермиләр, ә? Сөеп-сөелеп кенә яшәргә тиешле шушы изге җанның күкрәгенә сөю хәнҗәре батыр да, яңадан егетне утка сал, күзләрен күгәртеп көттереп йөр, янына да килмә, имеш. Харам бу туташка шагыйрьнең мәхәббәте. Менә бит ничек — егетне сөю газапларына дучар ит тә үзең шуннан тәм, ямь табып, качышлы уйнап йөр!.. Тамашачы кызларның барсында да Гөлсем туташка карата нәфрәт хисләре уянып өлгерде. Гөлсем туташның исә үз хәле хәл. Керфекләре эченә кереп йомылган ул, урындыгына бөтенләй сеңеп бетеп, тын да алмый утыра.

Такташ шигырь укылып беткәнче үк үзенең «акланганлыгын» сизеп алды. Котырынып кул чабулар-алкышлар астында, баштагы мәлдәгечә уңайсызланган кыяфәт белән тамашачыларга башын иде. Алкышлар көчәйде генә. Шагыйрь кулын күкрәгенә куеп, бераз гына тын торды, янә баш иеп алды. Шунысы гаҗәп, салам чәчләре инде башына чат ябышканнар, һич кенә дә хуҗаны кыен хәлдә калдырып маңгайга ишелеп тормыйлар иде. Такташ сәхнәдән сикереп төште һәм күңелендә уйнаган тантаналы хисләр эчендә урынына барып утырды. Утырган уңайга, үз итеп Гөлсемнең кулына кагылгандай итте. Моны күреп алган берничә кыз әлеге хәрәкәтне «бик үк урынлы» түгел дип таптылар. Шулай да аңа үпкә саклаучы беткән иде инде. Бу минутларда Такташны кичерергә онытып, һаман һушсыз көе сәхнә артында басып торучы бер генә кыз заты калды — ул Заһидә иде.

Шагыйрьдән соң да берничә номер башкарылды. Кыз һуш җыя алмый әле... Заһидәнең халәтен аңлаган Гайшә, кызның җилкәсеннән тотып, җилтерәтеп алды:

— Исеңә кил, ахирәтем,— диде ул. Заһидәнең әллә кая

төбәлгән төссез карашын күреп, Гайшәнең җаны куырылды. — Сәхнәгә чыгасың хәзер. «Әхмәтсафа Дәүләтъяров Такташның «Үтерелгән пәйгамбәр» дигән шигырен укый», — дип әйт. Җитте!.. — Ул чын-чынлап ачулана башлады. — Концертны өзсәң, бел — Заһид Шәркый институтта бер көн тотмый сине!

Шушы сүзләр тәэсиреннән булса кирәк, Заһидә айный төшеп сәхнә уртасына атлады. Тамагын кырып алуы сәер тоелды. Ул әллә нинди һавалы, ачулы һәм шул ук вакытта тормыш өчен бик тә мөһим нәрсәне мәңге табылмаслык югалткан чарасыз хәлдә залга карап торды да, батырланып, авызын ачты:

— Сөекле шагыйребез Һакташ... Такташ... — Шушы сүзләрдән соң, ни әйтергә икәнен онытып тукталып калды.

Беркайчан да сабырлыгын җуймаган Шәриф Камал Заһидәнең сүзләрен рифмага-көйгә салып дәвам иткән булды:

Һакташ, Такташ,
Син бит миңа якташ...

Зал көлеп җибәрде. Шушы хәл Заһидәне бөтенләй чыгырыннан чыгарып, беткән баш беткән, ник җимерелми дөньясы дигәндәй, залдагы көлешкән тавышларга битараф кына кулын селтәп дәвам итте:

— Сөекле шагыйребез... э-э... Пәйгамбәр... э-э... Үзең әйт инде... Торма күзеңне шардай ачып... — дип кычкырды да сәхнәдән чыгып йөгерде.

Әхмәтсафа чыккач, көлүләр тагын көчәйде. Заһид Шәркый басып залга ачулы караш ташлагач кына тынды студент халкы. Тик эш узган иде инде. Егет әсәрне укып китә алмый азапланды. Афзал Таһировның үзенә төбәлгән җылы карашын тотып алгач кына, егеткә җан иңде. Әхмәтсафа ачык тавыш белән:

— Һади Такташ. «Үтерелгән пәйгамбәр», — диде һәм шигырьне укый башлады. Әхмәтсафа, билгеле, Такташка караганда кайтыш укый иде, әмма шигырьне аңлап, аның эченә кереп укуы тамашачыларга шулай ук әйбәт тәэсир итте. Инде шигырьнең:

Кояш — шаһит: илем, иркем өчен
Сугышып йөрдем, әнкәй, ул күрде!
Зобанилар, явыз зобанилар,
Алар... Алар мине үтерде, —

дигән юлларына җиткәндә, күпләр тетрәнеп тешләрен кыскан иде. Кайберәүләрнең күзендә энҗедәй яшь елтырап, битләре буйлап аска тәгәрәде. Беркем беркемнән кыенсынмый, барсы да Такташның кодрәтле шигыре тәэсирендә, барсы да

икенче дөньяга — Такташның шигъри дөньясына кереп югалганнар иделәр.

Шигырь укылып беткәч, гөрләтеп кул чаптылар. Әхмәтсафа пәрдә артына кереп китәм дигәндә, шигырьдән үзе дә тәэсирләнгән Һади Такташ сәхнәгә кабат сикереп менде һәм:

— Булдырдың, брат, рәхмәт,— дип, нык итеп егетнең кулын кысты.

Әхмәтсафа сәхнә артына чыккач та үзен кулга алырга тырышты. Аның күңелен тырнап торган нәрсә — Заһидәнең сәхнәдә ялгышып, сәер хәлдә чыгып китүе иде. Ул аның өчен борчыла, кызны юатасы, тынычландырасы килә. Ләкин Заһидә сәхнә артындагы кечкенә бүлмәдә юк иде. Сәхнәдә Такташ яңа шигырьләрен укый, аңа котырып кул чабалар. Заһидәнең залда булмавына иманы камил, ашханәнең тар коридорына чыгып йөрде. Анда да кызны таба алмады... Күңелсезләнеп, егет кире сәхнә артына әйләнеп кайтты. Заһидә юк икән, аңа кичәне берүзе алып барып, төгәлләргә туры киләчәк инде...

Ә сәхнәдән Такташ тавышы килә. Ул канатлана-канатлана шигырь укый иде.

## IX

— Акыллы кеше беркайчан да революция ясамый! — моны Мифтах мөгаллим әйтте.— Бу эшкә, әгәр аны эш дип әйтергә яраса, йә наданнар алына, йә хөсет күңелле, явыз ниятле бәндәләр кулы белән ясала түнтәрелеш. Иң куркынычы — җанында кемнәндер ни өчендер үч алу тойгысы котырган иблисләр генә яскана инкыйлаб-фәлән дип. Акыллары томаланган бәндәләр саташа ул революция дигән нәмәрсә белән.

— Безнең җәмгыять авыру иде. Патша Рәсәе дип аталган бина череп беткән иде. Сүтмичә, җимермичә мөмкин түгел иде,— дип, аңа каршы төшүен дәвам итте губкомнан килгән вәкил.— Яңа тормышны үз кулларыбыз белән төзергә тиеш без. Кемдер килеп рәхәт дөньяга чыгарыр дип уйлау — хата! Үзебезгә ошаганча, җаныбыз теләгәнчә төзелер ул тормыш.

— Авыру иде, дисең, вәкил туган. Авыру кешене кулын кулга, аягын аякка аерып ташламыйлар, ә түземлек, сабырлык белән дәвалыйлар, аякка бастыралар. Аңлашылмый — кемгәдер нәрсәдер ошамый дип, булганны ват, туздыр, сүтеп ташла, җимер. Кем төзер кабаттан аларны?.. Ә бит төзергә, яңабаштан шушы ук нәрсәләрне корырга туры киләчәк. Кешеләрне аклар, кызыллар дип, төсләргә аерасыз. Яшелләр, каралар дип тә сөйләүчеләр табыла. Аңлы рәвештә болай

халыкны аерымлауның нәтиҗәсе аяныч булачак. Инде халыкның бәгыренә — дингә үреләсез. Монысы да гафу ителмәячәк! Рухыбызның көч алыр чишмәсе — дин. Әгәр бу эшегездән туктамыйсыз икән, дин-иман юлында шәһит киткән меңнәрчә батырларыбыз рухы сезне гафу итмәс! — Мифтах хәзрәт сәвит ызбасында утырган активка шелтәле караш ташлады. Ишек төбендәге почмакта бер-берсенә сылашып утырган Әхмәтсафа, Саттар, Әптериләргә төбәп күңелендәге рәнҗүен әйтмичә булдыра алмады.— Сез, оланнар, ялгыш юлга кергәнсез. Әйе, заманында мин үзем дә Каргалыга яңа тәртип урнаштыру нияте белән ашкынып килдем. Тик булганны ватып, җимереп түгел. Моңарчы авылда хөкем сөргән кадими тәртипләргә каршы көрәшнең бердәнбер вә дөрес юлы — балаларга җәдитчә белем бирү иде исәбем. Бу юлга өндәгән беренче кешеләрдән идем. Бәхетемә, теләктәшләрем күп булып чыкты ул чакта. Чөнки минем әйткәннәрем, өйрәткәннәрем халыкка аңлаешлы иде. Әйе, тәгълим-тәрбиядә яңалык, үзгәрешләр кирәк иде, әйе, балаларга дини белем белән беррәттән нигезле дөньяви белем бирү дә кирәк иде һәм мин, кадимилек сазлыгына кереп баткан хәзрәт, имамнар белән тартыша-тартыша, җәдитчә укытуны башлап җибәрдем. Сез минем иң беренче шәкертләрем булып, башыгыздан кичкән хәл-әхвәлләрнең барысына да шаһит булдыгыз. Безнең укыту бинасына ут төртергә маташтылар, мең бәлаләр белән юллап кайтарган әсбапларны туздырдылар, үземә, шәкертләремә кул күтәрүләр дә булды. Аталарыгызга кадимчеләр ниләр генә ишеттермәде... Түздек, тешне кысып түздек, күпме куркытсалар да, үгетләсәләр дә, юлдан тайпылмадык. Халыкның күпчелеге яңача укыту ягында булды, шул көч бирде безгә. Әмма мин дингә, иманга тузан бөртеге кадәр дә кер төшермәдем. Иман безнең калебтә, ул инде мең еллар буе ныгыган, алтын-мәрҗәннәрдән дә асылрак вә кыйммәтлерәк бер хәлгә килгән. Изгеләрдән дә изге иманга кизәнәсез икән, бик нык ялгышасыз, ай-һай нык ялгышасыз... Сак булыгыз, оланнар! Әгәр дә ки хәзер туктап калмасагыз, киләчәктә башларыгызга күп бәлаләр китерәчәк бүген кылган гамәлләрегез.

Мифтах хәлфә чыгып киткәч, сәвит йортында тынлык урнашты. Авыр хәлдә калган сыман хис итteләр яшьләр. Губком вәкиле генә сөенечен яшерә алмады: чакырусыз-нисез килеп, җыелышны тарата язган хәлфәгә ачуы чыккан иде аның. Ярый әле чыгып китә белде. Мифтах хәлфәнең авылда, бигрәк тә яшьләр арасында мөгаллим-остаз буларак нинди абруйга ия булуын үз күзләре белән күрде ул бүген. Шушы мөхтәрәм зат чыгып киткәч, вәкил моңарчы кулдан ычкынган тезгенне тагын үз кулына эләктерде.

— Ничек әйләндерә башны, ә? — диде ул, йөзен чытып.— Белеп сөйли... Совет хөкүмәтенең таянычы, алтын баганасы яшь көчләрдә икәнен аңлый. Күр син аны, шәрә артын умарта авызына китереп терәсе нәмә! Йә әйтегез, быелгы елны җәй буе яңгыр яумыйча, игеннәрнең янып-көеп бетүендә сәвит хөкүмәтенең ни гаебе бар? Ә бит Корбан бәйрәмендә, ягъни мәсәлән, гаеттә вәгазьчеләрнең һәркайсы сәвит хөкүмәтенә ябырылдылар, дини бәйрәмне коткы тарату, пропаганда өчен файдаландылар. Сез, кыю яшьләр,— вәкил дә ишек катында утырган яшьләргә мөрәҗәгать итте,— гаеткә каршы чаралар үткәреп дөрес эшләдегез. Теләгегезгә ирештегез дә. Муллалар сезнең басымга чыдый алмадылар. Унбер мәхәлләнең берсендә генә дә тыныч кына гает намазы укылмады, гаеттән файдаланып калырга ашыккан дошманнарга сәвиткә каршы корткычлык эшләре алып барырга ирек бирмәдегез. Так держать, Әхмәтсафа иптәш! — дип, үзенә якынрак утырган Әхмәтсафаның кулын кысты.— Без, өлкән буын,— губком вәкиленең үзен «өлкән буын» дип атавы бераз көлкерәк тоелды, чөнки кызыл гаскәрләр ягында бераз сугышып йөргән һәм яраланып шактый госпитальләрдә аунаган яшь кенә кеше иде әле ул,— сезнең белән горурланабыз. Моңарчы татар дөньясында «икенче Мәккә» дип аталган Каргалы авылында кыю яшьләрнең дини хорафатларга беренчеләрдән булып каршы төшүләре, һөҗүмчән чаралар оештырулары губком тарафыннан игътибарсыз калмас!

...Урамга чыккач, егетләр озак кына сөйләшмичә бардылар. Алдагы көннәрдәге күңелне кыздырып торган җилкенү, көрәш дәрте сүнгән, сүрелгән, җанда авыр бушлык кына иде. Көзнең соңгы ямьле көннәре үтеп бара, озакламый яңгырлар башланыр дип тә хафаланмый күңел. Сәбәбе шул: башка еллардан аермалы буларак, көзге кыр эшләре инде әллә кайчан төгәлләнде. Җәй буе җиргә өч-дүрт тамчы яңгыр тамдымы, юкмы. Илгә корылык килде. Игеннәр матур гына тишелеп чыктылар да рәхимсез кыздырган эссе кояш нурларына түзә алмыйча саргаешып, кибеп беттеләр. Иң бәхетле дигән кешеләр дә күп булса өч-дүрт капчык икмәк җыеп алдылар үз җирләреннән. Халыкны курку хисе басты — илгә шомлы адымнар белән, шыр сөякле кулларын сузып, ачлык дигән афәт килә. Ачлык котылгысыз иде. Ара-тирә сәвит җитәкчесе Зарифның: «Өметсезлеккә бирелмик, үз кулларыбыз белән яулап алган сәвит хакимияте күрә торып халыкны ачтан үтермәс»,— дип, күңелләрдә ышаныч, дәрт уятырга тырышса да, күпне күргән авыл мужигы моңа әллә ни ышанмады. Сәвит хөкүмәтенең ярдәмгә килүе мантыйкка сыешлы түгел. Башта «продразверстка» дип, аннан «прод-

налог» дигән булып, халыкның амбарларындагы соңгы икмәген дә талап алып чыгып киткән хөкүмәткә кул селтәгән иде инде алар. Революция дигәннәренә дә ышаныч беттегә чут. Дүрт еллап гомер үтте — һаман җимерү, һаман булганны тартып алу, халыкны талау. Төзегән бернәрсәләре күренми. Мондый илнең үзенә дә, хөкүмәт башында торганнарга да, әлбәттә, ышаныч юк. Авыз ачып әйтүе генә ансат — авылда гаскәр булмаган чак сирәк, әгәр эчеңдә генә асраган уй-фикерләреңне тышка чыгарып түксәң, дошман элемент дип, шәһәр төрмәсенә илтеп ябарга күп сорамаслар. Кулга алулар булгалап тора, аннан кайткан кеше генә күренми. Бер япсалар, нык ябалар сәвитнекеләр... Халыкка ни күрсәтер бу хөкүмәт, бер Ходай үзе белә. Халык дәшмәскә өйрәнә башлады. Бары дини йолаларны үтәгәндә — мәчеткә намазга җыелгач яки гает көннәрендә була торган вәгазьләрдә эчне пошырган хәлләр турында ачыктан-ачык сөйләшергә мөмкин иде. Шушы хәлне истә тотып, губком мәчетләрдә намаз укуларны чикләүче карарлар кабул итте. Урындагы фирка әгъзаларыннан, яшьләр оешмасында торучы комсомоллардан гаеткә каршы төрле чаралар үткәрүне таләп итә башлады. Бу — Мәскәүдән үк бирелгән күрсәтмә иде. Диннең тамырына балта чабылса, иман корый. Имансыз халык белән теләсә нәрсә эшләргә мөмкин булуын коммунистлар яхшы аңлыйлар иде шул.

Авыл өстендә шомлы тынлык. Үз тыкрыкларына борылып китә башлаган Әхмәтсафаны Саттарның тонык тавышы туктатты.

— Иртәгә мастерскойга төшәсеңме?

— Соңгы көн булыр инде, укырга китәбез бит...

— Шушы хикмәтләр белән йөреп, уку истән дә чыгып киткән,— дигән булды Саттар.

Быел җәй Әхмәтсафа көткәнчә булып чыкмады. Нигәдер Сакмар түрендәге урманнарны кисүдән тыйдылар. Гариф, иртә яздан ук артельгә кешеләр туплап, агач хәзерләү нияте белән Урал ягына китеп барды. Ышанып көткән өйлек бүрәнәнең тәтемәячәген аңлап алган Мостафа агай, барлы-юклы акчаларын җыештырып, сәүдә эшенә тотынып карамакчы иде, беренче сәфәрендә үк уңышсызлыкка очрады. Орск ягыннан вак-төяк сатып алып, Оренбурга кайтып барганда, соңгы вакытта күбәеп киткән угрылар, юлына каршы төшеп, әйберләрен талап алганнар. Үзен кыйнап, инде үлдегә санап бер чокырга ташлап киткәннәр. Ходайның рәхмәте беләндер инде, Мостафа агай, аңына килеп, якындагы станцага мәрәләп барып җитә алган. Миһербанлы бәндәләр очрап, аларның ярдәме белән көч-хәл Оренбурга, Гомәр абзыйларына кайтып егылган иде ул. Озак кына өендә кан төке-

реп ятты. Көзгә кергәндә, Госманның Кырымда, Перекоп дигән җирдә үлеп калуы турында хәбәр китерделәр. Бу хәбәрдән Мостафа агай бөтенләй биреште. Шәмсия Госманның үлү хәбәрен ишеткәч, нигәдер җилкенеп йөргән кебек иде, Әхмәтсафа беркөнне күреп алды, үги инәй лапаста үкси-үкси елый иде. Елады-елады да, үләне көеп беткән ишегалдын нидер эзләгән кыяфәттә бер әйләнде, ике әйләнде, өч әйләнде, аннан, берни булмагандай башын туры күтәреп, авыз эченнән мөнәҗәткә охшаган нәмәрсә көйләп, өйгә кереп китте. Аңламассың бу хатын-кызны... Хәлфи исенә төштеме, әллә яшьли әрәм булган йомшак күңелле Госманны жәлләп елыймы, монысын инде Әхмәтсафа белә алмады.

Үги инәй соңгы вакытларда диндарланып китте. Әхмәтсафа белән Саттар, алдагы елда уку елына бераз мая туплап булмасмы дип, Каргалыда итек тегү мастерское оештырып җибәргәннәр иде. Әхмәтсафа, үзенең Каеш кушаматына тугры булып, тире-күн эшенә оста булып чыкты. Белмәгәнен инде тернәкләнә башлаган әткәсеннән сорашты. Саттарның әтисе дә якын-тирәдә данлыклы итек тегүче оста иде. Үз осталыгын малаена да өйрәтеп өлгергән икән, эш шактый матур башланып китте. Үзләренә ярдәмгә тагын ике-өч егетне алдылар, алар арасында шактый үсеп, егеткә әйләнеп барган Әхмәтхан энесе дә бар иде. Башта, тәҗрибә өченгә үзебезнеке үзебезгә ярар дип, үзләренә итек тегеп киделәр. Тыryша торгач, ярыйсы килеп чыкты тагын. Итек-кәвеш эзләп шәһәргә йөрүдән туйган хәллерәк кешеләрнең дә егетләргә йомышлары төшә башлады. Аз-маз керем күренә башлагач, егетләрнең күңелләре күтәрелде, эш алга китте.

Яшьләрнең артель оештырып, үз көннәрен үзләре күрергә омтылулары хуплауга лаек иде. Губкомның яшьләр бүлегеннән озын чәчле бер егет килеп яз көне сәвит рәисе булып сайланган һәм фиркага да кереп алган Зариф абзый ярдәме белән авылда беренче яшьләр оешмасы — комсомол төзелде. Комсомолга керүчеләргә кызыл билетлар тапшырдылар. Бу оешмада торучыларның дингә каршы булып, үзләрен «Алласызлар» оешмасы дип тә җибәрүләрен ишеткәч, Шәмсия өйдә кара тавыш кубарды. Мостафа агай үзе дә улының һөнәргә өйрәнеп йөргән җирдән Ходайга каршы баручы көфер бәндәләргә кушылуын хупламады. Бөтен бәлане кызыл билеттан күреп, Шәмсия беркөнне Әхмәтсафаның сәке астындагы китаплар кәрҗиненнән егетнең билетын табып алып, мичкә ыргыткан иде. Моңа каршы протест йөзеннән Әхмәтсафа бер ай чамасы өйгә кайтмый, мастерскойда кунып йөрде. Протестка теләктәш булып Әхмәтхан да кушылды. Ул да озакламый комсомол булып китте. Боларны Мостафа агай авыр кичерде... Малайларның бөтен-

ләй эздән чыгу куркынычы алга килеп баскач, уллары янына Бибкәйне йөгертте ул. Егетләр дә бу хәлдән матур итеп чыгу ягын уйлап пошыналар иде.

Бибкәй, килеп:

— Әткәй икегезне дә өйгә кайтсыннар, диде... Кеше көлдереп йөрмәсеннәр, диде,— дип такмаклап бетермәде, Әхмәтсафа сөенеченнән сеңлесен кочагына ук күтәреп алды.

Көттереп торыш юк, егетләр, башларын түбән иеп, Тайфә карчыкның өенә кайтып керделәр. Әткәләре аякка басып, йорт арасында йөри башлаган иде. «Фетнәче» улларын күргәч, «ә» димәде, «җә» димәде, аларга кырын карап, бер генә мәртәбә аһылдап алды да, өйгә кереп, сәкегә менеп ятты...

— Оешмага кергән көннән сез инде кешеләр түгел, балакайлар...

— Кем соң без, алайса? — Саттар, үзе дә сизмәстән, Мифтах хәлфәнең шелтәле сүзләренә сорау биреп ташлады.

— Сез инде, балакайлар — әгъзалар хәзер. Һәркайсыгыз кәмсәмүл әгъзасы булып чутланасыз. Башкалардан аерым бер генә эш тә майтарырга тиеш түгелсез. Сүзегездән шуны аңладым. Гел бергә, гел төркем белән гамәл кылу. Бер-берегезгә кендек белән береккән кебек. Әле ул кылган гамәлне дә өстәгеләр кушуы буенча эшләргә тиеш буласыз. Өер кануны шундый — үз белдегең белән нидер эшләргә маташу һәрвакыт гаеп санала. Андыйларны җәза көтә.

Мифтах хәлфә мастерскойга итеген төзәттерергә биргән иде. Шуны алырга килгәч, комсомолга кергән егетләрнең күңел кылларын тартып карарга уйлады. Үзләренең ни кылганнарын беләме алар, егетләр белән ныклап сөйләшүче булганмы, үзләре бу хакта төптән уйлаганнармы? Хәлфәне шулар кызыксындыра иде.

Саттар, Мифтах хәлфәнең соңгы сүзләрен килештерми, кистереп әйтеп куйды:

— Өер түгел... Оешма! Яңа тормыш төзү өчен җанын да кызганмый торган яшьләр керә безнең комсомол оешмасына! Без ячейкада әгъза булуыбыз белән горурланабыз. Ә сез әгъза дисез...

— Өер ни, оешма ни, ике чабата бер кием бу очракта. Әгъза диме ни дисең — сез инде кәмсәмүл дигән хикмәтле организмның аерым бер әгъзаларын тәшкил итәсез. Тик шунсын белеп торыгыз —сез бу организмның куллары, бармаклары, эчәкләре кебек кенә. Башы да түгел, аягы да. Сез организмны яшәтү өчен иң шапшак эшләрне башкарырга тиеш. Шунсыз яши алмый ул. Өстәгеләр исә шуның сезгә бөтенләй күренмәгән чистарак, матуррак өлеше барын да белә-

ләр. Организмның рәхәт, ләззәт чигә торган өлешләре дә була. Ансы инде сезгә караңгы...

— Комсомолда демократия,— диде моңарчы сүзгә кушылмаган Әхмәтсафа.— Әгәр ул бозыла икән, без беркайчан да авыз ябып тормаячакбыз.

— Саттар дөрес әйтте, сез оешмага кергәндә ант иттегез. Җаныбыз да җәл түгел, дидегез. Хәзер ниндидер демократия, дисез. Җаныгызны демократия дигән серле нәрсәгә алыштыргансыз икән, ул демократия дигәннәре ни төслерәк була? Капшап, тотып караганыгыз бармы?.. Мин таныш сезнең оешманың демократиясе белән. Акка кара белән язылган — азчылык күпчелеккә буйсына. Өстәгеләрнең кушканы түбәндәгеләр өчен мәҗбүри диелгән. Шулай бит. Нәрсә килеп чыга? Ике төрле демократия бар икән. Берсе — өстәгеләр өчен, икенчесе — астагылар, ягъни түбәндәгеләр, сезнең кебекләр өчен. Өстәгеләр оешмасы миңа да, сезгә дә караңгы, балакайлар. Сез түбәндәгеләр оешмасы. Түбәнгә һәрвакыт ышанучан, әйткәнне үтәргә яратучылар җыела. Йомшак күңелле, ияреп китәргә яратучан кешеләр алар. Оешмасы да зәгыйфь холыклы булып чыга аларның. Шулай булмаса кемнедер яңа тормышка чыгарам дип, җанны корбан итәргә җыенамы адәм баласы? Кем өчен, ни өчен? Өстәгеләрнең сез баласы кебек — кушканны гына үтәп, тәүфыйклы булып кына йөрергә тиеш буласыз. Һәр кылган гамәлегез өстәгеләр өчен аңлаешлы һәм аларның мәсләгенә туры килсен. Менә нәрсә көтәләр алар сездән. Шулай булмаса, тыңлаусыз баланы шелек белән суктырган кебек, сезгә дә эләгә инде... Шелек кенә булып калса ярый да. Сез бит әле җаннарыгызны бирергә дип атлыгып торасыз.

— Мәгънәсез рәвештә гомер белән хушлашырга уйлаган юк анысы,— диде Әхмәтсафа уйчанланып.— Халыкны яңа тормышка чыгару, аларны бәхетле итү, аның хәсрәтен үзеңә алу теләге начармыни, хәлфә абзый?

— Аның бөтен кызыгы да шунда шул. Башкалар хәсрәтен үзеңнеке итәргә җыену чик-чаманы югалту дигән сүздер, балакай. Халык зур төшенчә ул. Аның хәсрәт-кайгысы дәрьядыр. Кайсын үзегезгә аласыз? Шунысы да бар — кайсы хәсрәтен кеше сезгә бирер икән... Һәркайсы үтә шәхси була бит аның. Халык дип гомуми әйтү — туры җаваптан качу өчен генә кирәк ул. Хакимнәр халык дигәндә бервакытта да үзләрен истән чыгармыйлар. Киресе булса, алар тарафыннан эшләнгән иң зур ахмаклык булыр иде ул. Һәр гамәлне үз файдасына бора хакимнәр. Хаким ихтыяры — беренче, халык — икенче. Сез исә халык беренче дип адарынып йөргән байгышлар. «Яңа тормышка чыгарыгыз»,— дип, гариза-үтенеч белән берәр кеше япыгызга килдеме әле?

Мифтах хәлфәнең көтелмәгән соравыннан Саттар югалып калды.

— Кем алай йөрсен инде...— диде ул, битараф тавыш белән. Мифтах хәлфәнең акыл сатуыннан туя башлаган иде ул. Губкомнан әллә никадәр эш кушып җибәрделәр. Һәр көнне шулай гомер уздырып, Мифтах хәлфә кебекләрнең фәлсәфәләрен тыңлап утыруга калса...

— Мин дә шулай уйлыйм шул.— Мифтах хәлфә хәйләкәр көлеп куйды.— Сезгә берәү дә гариза күтәреп килмәс. Башкалар турында уйларга сезгә өстән кушалар. Шулай бит. Вәт сез уйлыйсыз инде... Кеше турында уйлап, кысыр хәсрәтләр белән йөргәнче, балакайларым, үзегез хакында күбрәк уйласагыз, һөнәрле, белекле кешеләр булып җитешсәгез файдалырак булмас микән? Милләткә дим. Сезнеңчә — халыкка дисәк тә ярый. Берүк, кеше рухына, кеше җанына саксыз кагыла күрмәгез. Акылы үзендә булган кеше кемнеңдер үзе турында уйлавына мохтаҗ түгел. Шуны аңлагыз. Аһ, шәкерткәйләрем, кеше булып калсагыз иде сез, адәм баласы икәнлегегезне онытмасагыз иде...— Соңгы сүзләрен хәлфә ничектер егетләрне якын итеп, ышаныч белән әйтте.

Мифтах хәлфәнең сүзләре дөрес иде. Оешма булгач, аңа күрсәтмә бирүчеләр күбәя икән. Саттарны, комсомол ячейкасы рәисе буларак, губкомга чакырып, Корбан бәйрәменә каршы чаралар планы тоттырып җибәргәннәр әнә. Моңа кадәр бер дә дин-иманга каршы килердәй гамәл кылмаган егетләр башта шик-шөбһәгә төштеләр. Бергә җыйналгач, күмәклекнең көче шундадыр да, бәлки, кыюрак, тәвәккәлрәк кыланучылар да табылды. Аларга башкалар кушылды, шулай итеп, гаеткә каршы кичтә яшьләр җыены үткәрергә карар кылдылар. Губком әлеге адымны ике куллап хуплады. Өстәгеләрнең мондый теләктәшлеге яшьләрне тагын да дәртләндерде. Ячейка әгъзалары арасында гаетне бөтенләй үткәрттермәскә дигән фикер ягында торучылар да табылды. Әгәр Саттар белән Әхмәтсафа бу фикерне якласалар, күпчелек үткәрмәү ягында булыр иде. Тик егетләр, Мифтах хәлфә белән булган бәхәсне искә төшереп, артык кискен адымнан сакланырга сүз куешкан иделәр.

Яшьләр үзләренчә мәш килделәр, җыенга ныклап хәзерләнделәр. Мондый зур чараны беренче мәртәбә үткәргәч, хәстәрен күрми булмый шул. Гади чара гына түгел, гаеткә каршы чара ич... Авылдагы сәләтле, бу эштән шүрләмәгән яшьләрне җыеп, концерт әзерләделәр. Каравыл йортын клуб иттеләр, сәхнә ясадылар.

Бәйрәм алды киче җитте. Җыенга килүче булмас дип курыкканнар иде, яшьләр җыелды тагын. Әхмәтсафа, гадәттәгечә, үзенең гимнастик күнегүләрен ясап күрсәтте, декла-

мация сөйләде. Кемдер җырлады, кемдер скрипкада уйнады. Ут чыгарып биеп тә җибәрделәр. Кыскасы, яшьләр өчен менә дигән кичә булды. Ахырда Саттар яшьләрне гаеткә бармаска үгетләде. Анысы да шома гына үтте. Иң соңгы кеше булып, коммунист Зариф чыгыш ясады. Ул инде яшьләрне үзләре бармау белән беррәттән, өйдәге өлкәннәрне дә гаеткә җибәрмәскә чакырды. Монысына да каршы әйтүче, ыгы-зыгы куптаручы табылмады. Саттар белән Әхмәтсафа, җыенның шулай матур, шома гына үтеп китүенә сөенеп, өйләренә кайтып киттеләр.

Икенче көнне гаеткә киткән җиреннән Мостафа абзый яшьләренә тыгылып кайтып керде. Авыл картлары аны мәчет янына якын китермәгәннәр. «Балаңны урыс-көфер иттерденң, иманны таларга ябышкан эт үстереп ятасың», — дип, каһәрләп, каргый-каргый таяк-таш атып, кире өенә куып җибәргәннәр иде. Дин әһелләренең әйтүенә караганда, комсомоллар төнлә мәчет ишекләренә аркылы такта кадаклап куйганнар, гыйбадәт кылып төн үткәрергә җыенган мәчет картларын кыйнап, урамга чыгарып ташлаганнар. Барысын да исәпкә алсак, картларның ярсуы ни дәрәҗәдә икәнлеген аңлавы кыен түгел...

Мостафа абзый үзенең болай тиз кайтып керүенә аптырап калган Шәмсиягә бер сүз дәшмәде, сәке түренә намазлыгын җәеп, ялгызы гает намазына утырды.

Әхмәтсафа белән Әхмәтхан лапастагы сәндерәдә яталар иде. Әгәр бу вакытта өйгә керсәләр, тетрәндергеч күренешкә тап булырлар иде. Мостафа агайның төсен җуйган күзләреннән сыпылып чыккан ачы яшьләр бите буйлап чал сакалына агып төшә. Алдындагы намазлыгының чыланып бетүенә дә игътибар итмәстән, намаз укуын да онытып, шушындый изге бәйрәмнең ямен җибәргән, иманнан җәяүләп качкан бәдбәхетләрне ләгънәтли-каргый елый. Имансыз кавем арасында, картлар әйткәнчә, улы Әхмәтсафаның да булуына шикләнми иде ул. Дөньяны болгатучыларның башында Саттар белән Әхмәтсафаның йөрүе беркемгә дә сер түгел бит, нинди шик булсын ди.

Йөрәккә кара кан булып оешты әлеге тынгысыз көннәрнең шаукымы. Яшьләр бу эштә үзләренең катнашы булмавын исбат итәргә тырыштылар, картлар аның саен аларга каһәрләрен яудыра тордылар. Мостафа хастага әйләнде. Аягына басып, ишегалдында мәрәләп йөри башлаган иде, хәбәре биш елга бер килгән Фәтхулла авылга кайтып төште. Шәмсия бу хәбәрне ишетү белән һушсыз калды. Тәвәккәлләп, беренче ире янына, биатасы йортына төшеп киткән иде, кара хәсрәт эчендә кайтып керде. Фәтхулла аның белән

сөйләшеп тә тормаган. Хатынның шашынып, тилерә язып елавына да, туктаусыз Биккол адәме сөйләгәннәрне кабатлавына да игътибар итеп тормаган, ишеккә генә төртеп күрсәткән:

— Бар, Шәмсия, йөрмә монда, ирең янына кайт! — дигән, имеш.

Шуннан соң Тайфә карчыкның өендә яшәүчеләргә җәһәннәм тормышы башланды.

Әхмәтсафа бу уку елына үзе белән Әхмәтханны да алып китәргә уйлаган иде. Шәмсия кул арасына керердәй бердәнбер баланың да калага китүенә һич кенә дә риза булмавын сиздерде. Җай чыккан саен Мостафаның колак итен ашавын белде.

— Кая җибәрмәкче буласың Әхмәтханны? — диде ул беркөнне, ысылдаулы тавыш белән.— Өеңдә бер урыс булуы җитмәгәнме?.. Йорт арасында йөрергә, эшләргә кеше калмый. Үзең билсез калдың. Аркылы ятканны алып, торкылы сала алмыйсың. Ул малаеңнан да язасың киләме?

Мостафа бер сүз дә эндәшмәде.

...Әхмәтсафа белән Әхмәтхан Оренбурга китәсе кичне йокларга соң гына яттылар. Үзләренә күрә җитдиләнеп әзерләнделәр, сәфәр чыгар алдыннан барысын хәстәрләп, katkat күздән кичереп мәш килделәр. Башка вакытта сәндерәгә менеп кунаклагач та, йокы бүсә башламыйча, әле озак кына сөйләшеп, киләчәк матур тормыш хакында әллә нинди хыяллар корып яталар иде. Бу юлы исә өйдә генә йокларга булдылар. Әткәләре сүзен тыңлап инде. Уллары кичке аштан соң сәндерәләренә чыгып шылмакчылар иде, кисәк кенә әткәләре телгә килде:

— Кырпак төшәр вакыт җиткәнче яттыгыз бит инде ул сәндерәгездә... Бүген өйдә, рәхәтләнеп җылыда йоклагыз...

Әткәләре белән бәхәскә кереп торасы итмәделәр. Югыйсә егетләр сәндерәне үз итеп өлгергәннәр иде. Өйдә күзгә йокы керми генә менә. Өй тынлыгын бозып, авыз ачып сүз әйтеп тә булмый. Әвен базарына китә алмыйча, әйләнептулганып озак яттылар шулай...

Таң туганда, йокымсырап китә алдымы Әхмәтсафа, юкмы, әнисенең иңрәүле тавышыннан сискәнеп, сикереп үк торып утырды.

— Әхмәтсафа, тор, әткәгез...

Гайре табигый хәл булганлыгын аңлап алырга өлгергән иде ул. Йөрәге күкрәк читлеген каерып атардай булып бәргәләнә башлады. Колак пәрдәләре ертылыр дәрәҗәдә колагы шаулап алды. Бер мәлгә берни ишетми торды. Сәер сыкрау авазлары чыгарып башы гүли. Дөнья тонык шауга күмелде. Ул, таралып йоклап яткан Әхмәтханга эндәшеп тә

тормастан, аягына итекләрен җәһәт кенә кигәндәй итте дә әнкәсе артыннан чыгып йөгерде. Ишегалдында берәү дә юк. Тып-тын... Лапас ягыннан күңелне өтеп сыктау тавышы яңгырап алды. Ул шунда атылды. Лапас капкасы, беркайчан булмаганча, киереп ачып ташланган. Үги әнкәсе, кемдер килеп үзен шушыннан кубарып алудан курыккан сыман, капка баганасын ике куллап кысып кочаклаган да, үксеп елый иде. Әхмәтсафа Шәмсия янына килеп басты.

— Ни булды? Әткәй... кайда? — диде ул, калтыранган тавыш белән.

Таң шәфәгы дөньяга нурын чәчә башлаган мәл иде бу. Шушы сүрән яктылыкта Әхмәтсафа Шәмсиянең коточкыч йөзен күреп алды:

— Атагыз... үзенә кул салган... Башына җиттегез... Бәдбәхетләр... — Шәмсия лапас эченә бер адым атлады да кире чигенде. Куркуыннан дер-дер калтырый иде ул. Лапас эченә ишарәләп, пышылдап диярлек баягы боз салкыны бөркелгән сүзләренә ачыклык керткәндәй өстәп куйды: — Бау белән... Сәндерә астында...

...Әткәсен җирләгән көннәр кара төш кенә сыман. Аның үлеменә һич ышанасы килми Әхмәтсафаның. Зиһенен җыя алмый байтак көннәр йөрде ул. Бәгырьне талкыган нәрсә шул — әткәсенең мондый аяныч үлемендә туган-тумача, күрше-тирә фәкать Әхмәтсафаның гаебен күрде. Бөтен бәлане аның өстенә аудардылар. Әгәр ул динсезләнеп, көферләнеп йөрмәсә... Мәчетне аркылы такта белән кадаклап куймаса... Мәчет картларын кыйнамаса... Шушы хәлләр аркасында Мостафа мәчеткә йөрүдән мәхрүм калмаса... Ул чакта җанын хурларлык сүзләрне күп ишетергә туры килде егеткә.

Мондый хәлдә озак йөрү мөмкин түгел иде. Әхмәтханны укырга алып китеп булмады — ул Бөкре Бәдертдингә батрак булып урнашты. Әхмәтсафа исә соңара төшеп Оренбурга ялгызы гына укырга китеп барды. Әткәсенең кырыгын үткәреп, атна-ун көн вакыт үткәч, авылга кайткан иде, Тайфә карчыкның бикле өе генә каршы алды аны. Карчык үзе, Хәлфетдин югалгач, Каргалыга кайтмый да диярлек, каладагы кызында тора иде. Әхмәтсафа, аптырап, энесе янына йөгерде. Әхмәтхан, нәкъ әткәсе шикелле, сабыр гына хәлне аңлатып бирде. Шәмсия әнкәләрен, Бибкәйне дә ияртеп, Фәтхулла үз янына алып киткән икән...

Гөнаһысына кермик, Шәмсия башта бик каршы булган. Ирнең кайтып кергән көннәрдәге дуамаллыгы күңелен суытканмы, үзе генә белгән башка сәбәпләр дә булганмы, анысы инде безгә караңгы, әмма Фәтхулла аны кире үз янына кайтырга үгетләргә килгәч, Шәмсия кырт кискән. «Ходай язганга күнәргә кирәк, өлешемә төшкәне шулдыр, балалар ба-

лигъ булмыйча, ике аягымның берсен читкә атламыйм!» — дип, Фәтхулланы куып дигәндәй кайтарып җибәргән. Шәмсиянең үз өе дә унтугызынчы елгы янгында көлгә әйләнгән иде, Фәтхулла, юк-бар сәбәп табып, тагын тавыш чыгара калса, бөтенләй йорт-җирсез калудан да курка иде, ахры. Ничекләр сөйләшеп аңлашканнардыр, үткән атнадан бирле Шәмсия Фәтхулла белән кире кушылганнар. Кабат никах яңартып, бергә-бергә яши башлаганнар иде.

Әхмәтсафа, сеңлесе Бибкәй өчен борчылып, аягы һич кенә дә тартмаса да, Фәтхулла өенә юл тотты. Шәмсия белән Фәтхулла алдан сөйләшеп куйганнар идеме, икесенең дә сүзе бер булды: «Бибкәй өчен борчылма. Безгә ул үз балабыз кебек якын. Какмабыз, сукмабыз, кеше арасында ким-хур да итмәбез»,— дип, Әхмәтсафаның күңеленә җылы салдылар. Шәмсиядәге үзгәрешне күреп хәйран калырлык иде. Йөзе яктырып киткән, күз карашы әүвәлгечә нурлы, ягымлы иде. Әхмәтсафага да каты кагылмады. Кунакка сый-хөрмәт күрсәтергә тырышты. Үги инәй кат-кат әйтте:

— Берегезне дә чит итмибез. Аптырап, каңгырып йөрмәгез! Кайчан кайтып керәсегез килсә, шунда кайтыгыз. Ишек ачык, булганча сыен куярбыз. Үзегез дөнья көтә башлаганчы, сыйдырырбыз, иншалла,— диде ул. Аның тавышында ачу да, рәнҗү дә сизмәде Әхмәтсафа. Һәр сүзен Фәтхулла җөпләп торгангамы, Шәмсия бигрәк тә үз итеп, ышаныч белән сөйләде.

Сөенерлеге дә бар шул Шәмсиянең. Фәтхулла белән ике ара көйләнгән. Хатын соңгы елларда күрмәгән ир назы татыган, барлык аңлашылмауларга нокта куелган иде. Моның өчен Фәтхулла аз тырышмады. Теге чакта Шәмсиянең башын әйләндереп, аны чарасыз калдырган, ягъни үлде хәбәрен ирештергән Биккол адәмен барып тапты солдат. Күргән-кичергәннәрен дә Шәмсиягә җентекләп сөйләп бирде. Чыннан да, алар Биккол кешесе белән бергә булганнар, чыннан да, Фәтхулла яраланган булган. Яраларын ямап шактый вакыт госпитальдә аунаган. «Үз аягым белән кайтып кергәч, барысын да аңлатырмын»,— дип, хат язуны кичектереп торган. Терелеп чыккач, кайтырга әзерләнеп йөргән көннәрдә революция башланган. Ата улны, инә кызны белми торган мәхшәр... Тагын фронт, тагын үлем белән йөзгә-йөз очрашулар. Язасы хат һаман язылмый кала биргән, ирештергән хәбәрләреннән берсе генә килеп җиткән... Биккол адәменә килгәндә, ул җанына шактый гөнаһ алган булып чыкты. Аны, Фәтхулланы үлде дип, ялган хәбәр әйтергә күндерүче Шәмсиягә күзе кызып йөргән Вәлкәй хаҗи булган икән. Шәмсиянең барлык күргәннәренә дә шушы ялган хәбәр сәбәпче булганга, инде ялганны Фәтхулла үзе фаш

иткәч, ирнең күңеле кисәк йомшап, ул Шәмсиянең аягына килеп егылды. Әхмәтсафа килеп кергән вакыт — ир белән хатынның тормыш иләгендә аяусыз иләнеп тә, исән-имин кавышырга насыйп булуына тәмам ышанып бетеп барган чаклары, еллар үтеп тә сүрелмәгән мәхәббәтнең кабат дөрләп кабынган мәле, бәхетнең тулышкан сәгатьләре, сөеп-сөелеп туймаган көннәре иде.

* * *

Декабрь айларында ачлык бөтен дәһшәте белән үзен сиздерә башлады. Шәһәр урамнары хәер сорашып йөрүче бала-чага, сукбайлар белән тулды. Кышкы салкын иртәләрдә урамнарда туңып үлгән кеше гәүдәләре күренә башлады. Бөтен Идел, Урал буйларыннан халык Урта Азия якларына кузгалды. Бу кузгалыш моңарчы күз күрмәгән, колак ишетмәгән һиҗрәткә тиң иде. Анда барып өлгәшә алу — исән калу дигән сүз. Анда, бары анда гына икмәк бар дип уйлыйлар иде. Кызганычка каршы, бу бичараларның күпчелеге ярты юлга да барып җитә алмый, хәлсезләнеп, Оренбурда төшеп калалар. Бәхет эзләүчеләр торган саен арта, калада хәл торган саен мөшкелләнә бара. Ачлыкның һөҗүмен туктатып калу мөмкин түгеллеген аңлау зиһеннәрне тагын да чуалта, җанның җегәрен суыра иде. Берзаман урамда яткан мәетләр яныннан тыныч кына үтеп китәргә ияләнә башладылар. Үлемгә, афәткә ияләнү — үзе зур куркыныч. Кешенең киләсе көннәргә өмете киселү, һәрнәрсәгә, һәркемгә ышанычы бетү дигәнне аңлата иде мондый чарасыз битарафлык. Әхмәтсафаның бердәнбер куанычы дип әйтикме, җан тынычлыгы дип әйтикме, энесе Әхмәтхан белән сеңлесе Бибкәйнең чагыштырмача тук тормышта яшәүләре иде. Әхмәтханга килсәк, батрак тормышы җиңелдән түгелдер, тик эше авыр булса да, ачлык галәмәтен күрми, хуҗа миһербанлы бәндә булып чыкты. Ә Бибкәйнең хәлләре бигрәк тә әйбәт. Үги инәй белән үги әткәсе бу зәп-зәңгәр күзле, тузгак чәчле сөйкемле кызыйдан башка тормышларын күз алларына да китерә алмыйлар. Бибкәй — аларның үз кызлары, үз сөйкемле сөякләре. Тегесе дә, шулай бәләкәй көенчә, каян өйрәнгән диген, ярый да белә, үзен яраттыра да белә иде.

...Институт бинасы, күмер булмау сәбәпле, ягылудан туктады. Суык сөякләргә үтә. Дәресләр йокы бүлмәләрендә үткәрелә башлады, ашау ягы такы-токыланды. Өйдән ярдәм ала алмаган студентларның кайберләре, ачлыктан шешенеп, дәресләргә йөри алмас хәлгә килделәр. Аларга аз гына ярдәм итү дә зур мәсьәләгә әйләнеп бара. Бүлмәләргә буржуйка мичләре куелды куелуын, тик ягар утын юк. Утын

табу студентларның үзләренә йөкләнде. Бүлмәдәшләрнең берәрсе каяндыр ярма, бәрәңге кебек ризык таба калса, аны бергә пешереп, бергә ашап, бераз тамак ялгап-сипләп алган булалар. Оренбурда туган-тумачалары булганнарның да хәлләре шәптән түгел. Тамакны ныгытып булмаса, хет җылы өйдә төн чыгармын дип, Әхмәтсафа бер-ике мәртәбә Гомәр абзыйларына барып караган иде, кунак шәкертне сыйлау, җылыту түгел, карт белән карчыкның үзләренең хәле мөшкел булып чыкты — ашарларына ризык, ягарга утыннары юк иде. Әхмәтсафа, үзеннән өзеп булса да, аларга аз-маз азык илткәли башлады, килсә, утын хәстәрен дә күрә иде.

Шулай булса да студентлар тормышында истә калырлык хәлләр булгалый. Беркөн, кич кенә Гомәр абзыйларыннан кайтып керсә, бүлмәләрендә җанлылык хөкем сөрә. Курсташлары, моңарчы буш торган карават тирәсенә өелешкәннәр, нидер сөйләшәләр, көлешәләр. Әхмәтсафа бу галәмәткә аптырабрак тора иде, Сәгыйть, көр тавыш белән, аны үзләре янына чакырды:

— Егет, ник туктап калдың? Каушама, түрдән уз, таныш, Муса килде бит!..

Әхмәтсафаның аяклары ирексездән егетләр янына атлады. Шәрә караватта күзләрен елтыратып утыручы бүлтәйгән иренле, чандыр гәүдәле егеткә караш ташларга өлгерде. Шушы буламыни инде Муса дигән шагыйрь?.. Шагыйрь сүзе ничектер серле яңгырый. Бу сүзнең иясе дә хикмәтле заттыр кебек тоела. «Шагыйрь сүзе — телнең таҗы!» — дияргә ярата иде Мифтах хәлфә. Сүтеп-сүтеп тә сер очын табып бетереп булмаган бер йомгак сыман күз алдына китерә иде шагыйрьләрне Әхмәтсафа. Мусаны исә шагыйрь дияргә дә тел әйләнми. Ябык, кечкенә буйлы. Каян килеп сер йомгагы булсын ул? Сер төенчеге дисәң генә инде. Муса бик тере, хәрәкәтчән булып чыкты. Әхмәтсафа аягын өстерәп егетләр янына килеп җиткәнче, караватыннан очып кына төште дә күрешергә дип, кулын сузарга да өлгерде. Мусаның салкынча, арык кулын ныгытып кысарга да уңайсыз. Әхмәтсафаның башыннан шундый уй сызылып үткәнне сизгән шикелле, Муса яңа танышының кулын шатырдатып кысып алды.

— Әйдүк, туган,— диде Муса. Егет үзен мондагы һәркемнән өлкән хис иткән кебек сөйләшә. Һәм бу шулай иде дә бугай.— Сәгыйть әйтеп өлгерде, Муса Җәлилов дигәннәре мин булам инде.— Ис китмәгән рәвештә өстәп тә куйды:— Шигырьләр язам...

Егетнең тавышы Әхмәтсафа күргән шагыйрьләрнекенә бер дә охшамаган. Әнә Такташның тавышы нинди матур яңгырашлы, үзе йомшак, шул ук вакытта көчле дә. Мусаның

исә тавыш дисәң хәтерең калыр —юка гына... Кабыгы әрчелмәгән бәрәңге кебек шома тавыш.

— Әхмәтсафа Дәүләтъяров...

— Беләм, ишеткән бар,— диде Муса көлемсерәп. Ул янә караватына килеп утырды.

Менә шунда бугай хикмәт. Ачык йөз белән елмаеп сөйләшүе, башкаларны игътибар белән, көлемсери төшеп тыңлавы егетне ничектер өлкәнәйтеп җибәрә, башкаларга караганда бер башка өстен куя сыман иде.

Ул, үзен сырып алган егетләргә аңлаткандай, сөйләнеп алды.

— Авырып китмәсәм, мин дә сезнең кичәләрдә теләп катнашыр идем дә... Озакка кереп ятарга туры килде. Госпитальдә чагында Гайшә килгәләп йөрде минем янга. Шәп декламатор Дәүләтъяров белән читтән торып таныш инде мин. Аннан үткән ел Мостафага губкомнан иптәшләр еш киләләр иде. Шәһәр тормышы, ТИНОдагы хәлләр белән таныштырып тордылар. Шулай, белми дип уйламагыз, монда шылт итсәгез дә, ул хәбәр атна эчендә миңа килеп ишетелде.— Ул янә елмайды. Мусаны яхшы белгән, аны сагынып беткән иптәшләре күңелле шаулашып алдылар.

— Гайшә — синең магнитың инде. Тикмәгә йөрмисең егет! Шул магнит тартып китергәндер әле бүген дә монда үзеңне,— диде Габдулла Амантай.

— Авылың Мостафада тик ятмадың. Без дә күзсез-колаксыз түгел, Муса агай. Бөтен губернага яхшы атың чыкты, даның таралды,— дип көлә-көлә сөйләнде Сәгыйть, кунакның салпы ягына салам кыстыргандай. Сәгыйть — хәйләкәр төлке, ялгышмады. Бу сүзләрне ишетү Мусаның үзенә дә бик күңелле иде, ул шул арада эшем иясенә әйләнеп, җитдиләнеп китте.

— Яшьләр, балалар белән эшләүне һәркайсыбызның намус эше, бурычы дип саныйм. Мин генә түгел, губкомдагы иптәшләр дә шулай уйлый. Иптәш Ленинның һәр чыгышы яшьләр, балалар тормышын яңача үзгәртү рухы белән сугарылган. Партиянең һәр адымы шуңа юнәлтелгән. Без аларны, кулланма итеп алып, тормышка ашыру юлында ару-талуны белмәскә тиешбез.

— Сәяси курсларда укып, чын комиссарга әйләнгәнсең,— диде Фатыйх Сәгыйтов.— Ә ачлык хакында ни әйтә иптәш Ленин? Халык кырылып бетмәсме?

— Бетмәс,— диде Муса. Сүзләре ышанычлы булсын дигән төсле, тып итеп идәнгә басты.— Чит илләр, бигрәк тә Америка ярдәм күрсәтүне оештырды инде. Без аны Оренбурда да сизәбез.— Муса, җитди эше исенә төшкән сыман, кашын җыерып бер мәлгә тын торды. Чыннан да, китәргә

җыена икән, ашыгып саубуллаша башлады. — Ярый, егетләр, хушлашабыз. Без — сәяси мәктәп курсантлары, кулга мылтык тотып, төннәрен шәһәрне сакларга чыгабыз. — Әхмәтсафа шуны күзәтеп алды — Муса үзенең һәр сүзенә, һәр гамәленә ышаныч белән карауларын тели иде. Бу юлы да шикләнергә урын калмасын дип аныклый төште. — Складларны, кибетләрне сакта тотарга туры килә. Шәһәр тулы шпана, угры. Дошман элементларының күп булуын да истән чыгармаска кирәк, егетләр. — Ул, сине оныта язганмын, гафу ит, туган дигән кебек, кисәк кенә Әхмәтсафага төбәп сөйли башлады. — Шулай, Дәүләтъяров иптәш, көрәш бер генә минутка да тынмый илдә. Сез дә читләшмәгез! Бу көрәштән читләшү — аңлы рәвештә дошман тегермәненә су кою белән бер. Безнең иман, безнең инану бер — илдә социализм төзү. Кирәк булса, яңа тормыш өчен корбан да булырбыз. Тик шуны хәтердә тотарга кирәк — ул корбаннар эзсез югалмаячак! Алар яңа тормышның беренче ташлары, кызыл кирпечләре булачак. Ә каһарманнардан аккан кан ул ташларны ябыштырачак иң ныклы җилем булыр, — диде, акыл биргәндәй. Хәзер инде, бу сүзләрдән соң, каршыларында чандыр гәүдәле, йолкыш кыяфәтле үсмер түгел, бәлки, әзмәвердәй Муса торганына беркем дә шикләнми иде бугай. Корбаннар хакындагы ялкынлы сүзләреннән Мусаның күзенә яшьләр килгән иде. Әхмәтсафа үзәге өзелердәй булып аны да, үзен дә жәлләп куйды. Ни өчен йөрәге урыныннан купты?.. Бу минутта ул аны һич кенә дә аңлата алмас иде. Келт итеп Мифтах хәлфәнең яңа тормыш хакындагы сүзләре исенә төште дә аркасына салкын тир бәреп чыкты. Сәер иде бу халәте. Менә сиңа сер төенчеге! Күңелен әллә нишләтеп җибәрде бит кана!.. Муса, Әхмәтсафадагы үзгәрешне сизгән кебек, аңа тагын бер мәртәбә сынаулы караш ташлады да, серле елмаеп, чыгу ягына кузгалды.

— Акыл бирү җиңел лә ул, тамак ачыкса, күзгә әпәйдән башка бернәрсә дә күренми, — диде Фатыйх, инде чыгып киткән Муса белән бәхәскә кереп. Ул, лыштыр-лыштыр атлап, буржуйка янына китте. Бүген аның кизү көне икән. Төн җиткәнче ничә тапкыр бәхәскә керер: кемнедер тәнкыйть итәр, кем беләндер әрепләшергә өлгерер, әмма шунысы хак: бүлмәгә җылы төшүе икеле булачак бүген.

Кайчандыр бергә сабак алган иптәшләре Мусаны озата чыгып киттеләр. Бүлмәдә ике-өч кенә студент калды.

— Менә кем икән ул Муса... — диде Саттар, зур яңалык ачкандай. Яшь шагыйрь Муса Җәлил белән очрашу аңа да тәэсир иткән.

Шушы аз гына булып алган очрашу Әхмәтсафа өчен дә эзсез үтмәде. Муса ни хакында сөйләгәнен үзе яхшы белгән

кебек... Башкаларның да шуңа төшенүен, белүен, үзләштерүен тели иде шикелле. Шул чагында гына ул сине үзенә иш итәр, синең белән эч серләрен уртаклашыр, очрашканда иптәшләрчә кулын сузар. Үзенә тулысынча ышанмаганнарга ул борылып та карамаячак. Әхмәтсафа ышанамы аңа? Беренче күрүдән, беренче сөйләшүдән соң ук әйтүе кыен. Иң сәере шул: Муса яңа танышының үзенә ышануын бик тели иде бугай. Кат-кат аңа сынаулы караш ташлавында шушы мәгънәне, шушы ихтыярны тотып алды Әхмәтсафа...

Соңыннан шагыйрьнең дусларыннан белде: Мусаның үткән ел әтисе үлеп киткән. Үзе озак кына авырып яткан. Укуын өзәргә туры килгән. Аннан туган авылы Мостафада яшьләр оешмасы төзегән, шактый маһирлык күрсәтеп өлгергән егетне укытучыларның губерна съезды делегаты итеп сайлаганнар. Быел җәй, ачлыктан качып, Оренбурга килгән булган. Шул ачлык аркасында аздан шпаналарга ияреп китмәгән. Фатыйх дөрес сукалый, ачыкканда Ленин сүзләре тамак туйдырмый икән. Мусаның бәхетенә каршы, элекке хәлфәсе Нургали абый Надиев очрап, аны мең бәлаләр белән хәрби-сәяси мәктәпкә курсант итеп урнаштыруга ирешкән. Монда нәкъ менә шагыйрьлеге ярдәм иткән, диделәр... Муса кулына корал тотып, ак бандаларга каршы көрәшеп йөргән. Соңгы айларда янә авырып китеп, госпитальдә яткан. Терелеп чыккач та, беренче эш итеп, үзенең сабакташлары янына килгән. Боларны ишеткәч, чыннан да, Муса Әхмәтсафа алдында ике-өч башка үсеп китте. Аңа ихтирамы артты. Ышанырга була иде Мусага...

* * *

Кыш урталарында мәгариф институтына җитәкче булып моңарчы хәрби-сәяси курсларда мөгаллимлек иткән Нургали Надиев кайтты. Элек тә «Хөсәения» мәдрәсәсендә эшләп, шәкертләр арасында абруй казанган. Таләпчән, әмма миһербанлы шәхес. География һәм хисап укыта иде. Институт директорының хәрби эшләр буенча урынбасары итеп Заһид Шәркый билгеләнде. Бу ике укытучы артыннан моңарчы хәрби-сәяси курсларда укыган яшьләр дә институтка күчеп килделәр. Алар арасында Муса да бар иде.

Муса тулай торакта бер генә кич кунды.

— Монда озак түзеп булмас,— диде ул кизү торган Әхмәтсафага. Бүлтәебрәк торган салынкы иреннәрен бөрештереп, башын югары күтәрә төшеп, һавага әкрен генә җылы тынын бөркеде. Авыздан чыккан тын, аксыл пар-томанга әверелеп, сыек агым булып түшәмгә күтәрелә башлады. Бу күренешкә мәгънәле итеп карап торгач, тагын кабатлады.—

Озакка түзмәм мин монда, туган. Әле авырудан терелеп тә җитмәгән мәхлук бит мин. Тәрбия кирәк миңа, тәрбия...

Әхмәтсафа ни дип әйтергә дә белмәде. Соңгы вакытларда тулай торакны җылыту өчен утын табу бер бәла булса, озак вакытлар ачлы-туклы яшәү дә үзен нык сиздерә. Хәлле гаиләдән дигән студентларга да өйләреннән ярдәм килү өзелде. Авыллар ачыга иде. Авылга карап торган шәһәрнең хәле биш мәртәбә мөшкелрәккә әйләнде. Әле күптән түгел генә студентларның гомуми җыелышы булып, профсоюз комитетына сайлаулар үткәрделәр. Профком рәисе итеп оештыру эшләренә маһир Фатыйх Исхаков, ә аның урынбасары — хуҗалык эшләре өчен җаваплы итеп Әхмәтсафа Дәүләтъяров сайланды. Үзләре комитетка үтмәгәнгә эчләре пошып йөрүчеләр үткәндә-сүткәндә бәйләнеп калалар:

— Әй комитетчик, кайчан җылыга тиендерерсез студентларны? Нигә утын ягын кайгыртмыйсың?! Алайса, ник сайлап куйдык сине профкомга?..

— Әхмәтсафа, ашханә эшен тикшерүне оештырырга кирәк. Көннән-көн шулпа сыегая бит... Әллә үзең дә поварлар белән әшнәләшеп киттеңме?

Монысы инде ачыктан-ачык яла ягу. Бу сүзләрне иң еш кабатлаган кеше Мәҗит иде. Әмма үпкәләшеп, аңлашып вакыт үткәреп йөрисе юк, хәлләр чыннан да җитди төс алды — ачлыктан котылу чарасына керешергә кирәк иде.

Профком җыелышы үтеп, ике көн үтүгә, Әхмәтсафа «Орлес»ка (Оренбур агач эшкәртү заводы) барып, институттан алган кәгазе янына губкомнан яздырып алган белешмәне дә кушып, завод җитәкчеләре белән килешү төзеп кайтты. Килешү буенча студентлар завод эшчеләренә культура-агарту хезмәте күрсәтүне үз өсләренә алдылар. Кирәк чакта эшче көчләр белән дә тәэмин итәргә туры килер, ә завод үз чиратында гамәлгә ярамаган агач, такта кисәкләреннән институтка да өлеш чыгарырга ризалашты. Шулай итеп, суыктан котылу мөмкинлеге табылды.

Бу Әхмәтсафаның җәмәгать эшчәнлегендә беренче сизелерлек җиңүе иде.

Гомәр ага егетнең җәмәгать эше дип янып йөрүенә каршы килмәсә дә, бу хакта фәлсәфә куертып алды. Ул көнне Әхмәтсафа «Орлес»тан кайтышлый, шактый олыгаеп баручы агайның хәлен белешмәк булып, өйләренә сугылып кына китмәкче иде. Гомәр абзыйларга килеп кергәч үк, гәүдәгә рәхәт җылылык сарылды. «Май кебек өйләре»,— дияр иде берәү булса, суыктан мондый өйгә килеп кергәч. Агайның да кәефе күтәренке, Әхмәтсафаның керүенә сөенеп, карчыгына чәй куярга кушып, кунакны түр якка чакырды. Соңгы вакытларда сирәк тиенгән мондый рәхәтлекнең сәбәбен дә

әйтеп өлгерде: Җаек аръягындагы касабчы туганы бер олау утын китереп бушаткан, шактый гына ризык та алып килгән. Агайның кат-кат сөенеп әйтүенчә, аларны җәннәт капкасы төбендә калдырып киткән икән.

— Менә син, Әхмәтсафа энем, җәмәгать эшләре белән йөреш, дисең... Бездән дә үтте ул дәвер. Җәмәгать, милләт файдасына шактый игелекле гамәлләр кылынгандыр. Кем исәпкә алган аларны. Җәмәгать файдасы диләр бит аны шуның өчен дә. Җегәрең, дәртең ташып торганда нидер эшлисе килә, милләтне тәрәккый җибәрәсе килә. Вәт, эшләп тә куясың күңелеңә яткан бер гамәл. Аны кычкырып та йөреш юк, кеше күрсен дип тә уйламыйсың. Кемдер рәхмәт әйтсә, сөенеч, билгеле. Күбесе эзсез үтә инде андый эшнең. Әйтәм бит, ул җәмәгать дигәнең андый нәрсәгә тиз ияләнә. Сине һәрдаим шулай башкалар кайгысы белән көеп, алар хәсрәте белән янып-көеп яшәргә тиеш дип уйлый башлый. Кылган гамәлеңә күз йома, сүлпәнләнсәң, ризасызлыгын белдереп сөрән сала. Эшне, энем, рәхмәт әйтсеннәр өчен эшләмиләр аны. Башкалар файдасына кылган гамәленә тау кадәр рәхмәт көтеп йөргән кеше — җүләр кеше ул. Иң зур җүләрлек шул. Игелек кыл да елгага сал, халык белмәсә, балык белер... Синең белән гәпләшә башлагач, күңел кузгалып куйды. Гөрләп тора иде шул җәмәгать тормышы калада. Эш күрсәтүне егетлеккә саный торган идек. Җаның кушканга, вөҗданың әйдәкләгәнгә кылына андый гамәл. Ә син, сайлап куйдылар, ышаныч күрсәттеләр, дип авыз ерып утырасың...

— Дөресе шул булгач...— Әхмәтсафа Гомәр агайның тел төбен аңлап бетерә алмый иде. Шуңа күрә тагын да ни дип әйтергә дә белми туктап калды.

— Хагын хак та, агын ак та, кара дияргә кушкач, кара дибез инде... Шулаймы? — Гомәр агай, көлеп, егет алдына икмәк кисәге куйды.— Әйдә, чәеңне эч әле. Мине тыңлап утырсаң... Карт кешенең үткәннәрне исенә төшереп үтә гомере. Эт картайса — койрыгын сөйрәр, адәм картайса — үткән гомерен сөйләр, ди... Мин карап-күзәтеп барам, сәвит хөкүмәте халыкны бушка эшләтергә күнектермәкче була. Әле шимбә өмәсе дип пыр тузалар. Ул өмәләр атнага биш көн уза башлады бугай. Һәркем җәмәгать эше дип чабулый, һәркем эшлекле, мин сиңа әйтим. Ил ачлыктан кырылып бетеп бара.

— Шуның өчен дә йөрү бит инде, Гомәр абзый. Ничек тә бәндәләргә җиңеллек китереп булмас микән диюнең эше. Бүген «Орлес»ка барып, студентларга утын китерү мәсьәләсен хәл кылдым. Начар түгелдер бит? Мин йөрмәсәм, кем йөрер?

— Һәй егет, мактанасың килә. Эш күрсәтергә маһир син,

анысына сүзем юк. Кешеләр белән уртак тел таба алуың да әйбәт. Эчкерсез күңелле, булдыклы егет. Дәүләтъярныкы икәнлегең әллә каян күренеп тора. Мин шуны төшенеп бетә алмыйм: шәкертләргә утын ягын кайгыртучы кеше бардыр бит мәдрәсәдә? Ул нишләп йөри бу вакытта?

— Аның да эше җитәрлек. Монда минем сүз үтә, шуңа күрә мин йөрим.— Әхмәтсафа бу сүзләрне чын күңелдән әйтте.— Элекке чор түгел, Гомәр абзый. «Моны эшлим, монысын эшләмим»,— дип, үз көебезне көйләп йөрер вакытлар үтте инде. Яңа тормыш шулай гына төзелә ала. Ирекле, аңлы хезмәт...

— Җитте, энем, тирән керә төрәнең, көчлек килмәсен.— Гомәр агайның тавышына мыскыл кушылган иде.— Шуны гына әйт әле, син заводта утын кайгыртып йөргән вакытта башка шәкертләр кайда булдылар?

— Кайда дип... Дәрестә инде...

— Синең сабак калды инде болай булгач. Хәлфәң ни дияр?

— Сүз әйтмәс, Гомәр абзый. Директорның махсус рөхсәте белән йөрим бит мин... Мөһим эш артыннан чапканны укытучылар аңлый. Начар билге куймаслар.

— Менә ничек килеп чыга — башкалар белем ала, син җәмәгать эшендә. Моның өчен сиңа яхшы билге дә куялар. Шулай бит?

— Шулайрак булып чыга. Хәзер заман шундый.

Гомәр агай көйләп алды:

— Заман кемнең заманы... Идегәй батыр турында ни беләсең? Кыйссасын ишеткәнең бармы?

— Булмыйча! Мифтах хәлфә бикләтте дә әле.— Әхмәтсафа, көттереп тормыйча, кайчандыр күңеленә бикләгән юлларны яңартты:

Илем өчен илсенеп,
Җирем өчен җирсенеп,
Халыгым өчен яхшы уем.
Күкрәк тулып җилсенеп,
Көрәшкәнне халыгым
Аңладымы — белалмам!
Аңламаса халыгым
Аңламастан үлалмам!

Идегәй кебек шөһрәтле каһарманнарның да халыкка хезмәт итеп, аның өчен тиешле әҗерен аласы килгән бит, Гомәр абзый. Һәрхәлдә, үзен аңлауларын, ил батыры итеп санлауларын теләгән, кылган гамәлләре өчен рәхмәт тә ишетәсе килгәндер. Ил өчен, халык өчен хезмәт итү бүген генә килеп чыккан нәрсә түгел инде...

Гомәр агай җавапны көттермәде:

...Бозгынлыкта калган ил —
Аның көне кемгә охшар?
Кичәге киткән атамның
Менгәне — кеше аты икән,
Сауганы — кеше биясе,
Җиккәне — кеше дөясе.
Алты айлык агыр йортыңнан
Урын тапмый, атамның
Киселеп китте җөясе,
Аның көне кемгә охшар?..

Шулай, энем... Мин һич тә сине халык, ил мәнфәгате өчен гамәл кылма, димим. Дөрес аңла. «Агач башын җил борыр, адәм башын сүз борыр», — дигән ул дастанда. Үземнекен тукып, аңышмыйча, сине эздән чыгарасым килми. Кулыңнан килгәч, сиңа бик күп өярләр әле ул җәмәгать эше дигәннәрен. Син эшләрсең, аннан башкалар файда күрер. Тирәңдә һәрвакыт бушбугазлар тулганыр, кылган гамәлләреңнең әҗере дә шуларга эләгер. Андыйлар әрсез, шома, хөсет күңелле була. Мин, Дәүләтъяр ыруының иң карт кешесе, үземнән соң җөянең — нәсел җебенең нык булып калуын телим. Шул чагында гына бу дөньядан тыныч күңел белән китә алам. Үзең дә аңлап бетермәстән, төрле ызгышларга юлыгып, яшьтән җегәреңне юк дауларга әрәм итмә, дим. Синең тирәдә шома кешеләр күп йөрер. Булдыклы затларны ярата алар. Җәмәгать эшлеклесе дигән булып, укуыңны онытып, башкалар эшләргә тиешле эшне син майтарып йөреп, ахыр чиктә, надан калып, кеше хуры булып бетүеңнән дә куркам. Җәмәгать эше дигән нәрсә, әрсез алабайларга киләчәктә түрәлеккә юл ача. Белемеңдә, кулыннан эш килгән асыл затлар түгел, сүз сөйләп шомарган фәхеш бәндәләр менеп атлана тәхеткә бу заманда. Синең кебек егетләрне сытып кына үтәчәк алар. Сак бул, энем, куркыныч дәвер килде сезгә...

Нургали Надиев егетнең булсынга йөрүенә куанып, очрашканда болай гына узып китми инде. Хуҗалык эшләренә караган мәсьәләләр хакында фикер уртаклашудан да тайчанмый. Шундый ышаныч бар чагында сынатасы киләме соң! Мондый вазгыять егетнең үзенә дә охшый. Башка студентларның төшләренә дә керми, син исә олы кешеләр — директор, аның урынбасарлары белән кул биреп исәнләшәсең, хәл-әхвәл сорашмый җибәрмиләр сине. Зарланып тормыйсың, билгеле. Хәлләр ничек кенә хөрт булса да, зур кешеләр янында егет булып каласың килә, зарланмыйсың. Гомәр агай дөрес әйткән, Әхмәтсафага эшне өеп кенә торалар. Егет исә тапшырылган һәр эшкә җаваплы карый, кушканны гына көтеп тормый, үзе оештыра, үзе таба. Әхмәтсафа кайгырта башлаганнан соң, утын дип хәсрәтләнәсе бетте менә. Мондый булышчы табылуына директор сөенә иде.

Шулай җилкенеп йөргән көннәрдә тулай торакка кайтып кергән Мусаның нәкъ Әхмәтсафага карап, аңа бәйләнгән сымаграк, кат-кат «салкын монда, түзеп булмас» дип сөйләнүен өнәп бетермәде ул. Хәзер түзәргә булыр, әле атна-ун көн чамасы мондагы хәлне күрсәң... Уйлары Әхмәтсафаның йөзенә чыккан иде. «Нәрсә эшләргә соң? Һәркем шулай сукранып, ыңгырашып утырса, кемдер китереп бирер дип уйласа, билгеле, түзеп булмас. Бөтен тулай торагың белән катып үләрсең...» Әхмәтсафаның карашы шелтәле иде. Һәрнәрсәгә үтә сизгер, каршылыклы хәлләрдән оста итеп чыгарга өйрәнеп килүче Муса Әхмәтсафаның карашын тиз тотып алды, зарлануыннан туган уңайсыз хәлне төзәтү юлына басты:

— Дустым, зарланып эш чыкмас,— диде ул, әле яңа гына дөньясы җимерелгән кебек сыктап торуын онытып.— Мин бүген үк кызлар белән сөйләшәм. Үзешчән сәнгатьтә катнашучы, әле мин белеп бетермәгән егетләр дә бардыр.— Ул инде Гайшәдән кемнең нindiрәк артистлык һөнәре барлыгы хакында белешкән иде. Гомумән, яшьләрне үз тирәсенә туплау өчен аңа артык тырышлык та кирәк түгел иде сыман, ике-өч җөмлә әйтүгә, тирәсендә кыз-кыркын бөтерелә башлый. Кызлар янына егетләр тартыла. Муса үзе гел читтә калган шикелле тоела. Әмма егет беркайчан да дилбегәне кулыннан ычкындырмый. Яшь-җилкенчәкне кыздырып җибәрү осталыгына ия ул, моны яхшы аңлый, кирәк чакта бу осталыкны эшкә җигеп тә алгалый иде. Әле генә үзен шелтәләп торган Әхмәтсафага күз кысты.— Үзең дә сәхнә йолдызына әйләнеп барасың икән. Синең кебек егетләр кирәк миңа. Язган ике-өч пьесам бар. Мин монда укып йөргән элекке елларда сәхнәдә уйнаган идек. Сәгыйть яхшы белә инде.— «Пьеса» сүзе ишетелүгә алар янына елышкан Агишев, Мусаның сүзен раслап, дустанә баш селкеде.— Менә бит егетләр әле дә онытмаганнар,— диде Муса, күңеле булып.— Шул пьесаларымны яңадан карап чыгам, бәлки, тагын эшкә ярарлар.— Ул җитди тонга күчте.— Шәһәрдә мәктәпләр, балалар йортлары, эшчеләр коллективлары аз түгел, студентларның шефлык рейдларын оештырырбыз. Бәлки, ашау ягын да кайгыртырга мөмкин булыр.

Сәгыйтьнең аксыл йөзенә яктылык таралды. Мусаны хуплавын белдереп, күгәрчендәй гөрелдәп алды:

— Шәп булыр ие ул, Муса. Әхмәтсафа берүзе ике-өч әртисне алыштыра. Декламация дә сөйли, спортчы да...

— Нинди шагыйрьләрнең әсәрләрен укыйсың,— дип кызыксынды Муса. Хәзер инде ул бая Әхмәтсафа каршысында шәлперәеп басып торган кызганыч кыяфәтле малай-шалай түгел. Дилбегә Муса кулында иде.

Әхмәтсафа кинәт үзенең артистлык һөнәренә бәйләнә башлауларына кыенсынып кына җавап бирде:

— Тукай... Сәгыйть Рәмиев... Дәрдемәнд... Санап үткән шагыйрьләрне авылдагы мөгаллимебез Мифтах хәлфә ярата иде. Безгә дә өйрәтте әсәрләрен.— Корбан гаете алдыннан Мифтах хәлфәнең рәнҗешле сүзләрен искә төшереп, төртелеп калды.

— Шәп, бу шагыйрьләр белән яшәргә була! — диде Муса, белдекле кыяфәт белән.— Тик алар иске бит инде. Искегә тисәң, исең китәр. Яңалар белән кызыксынмыйсыңмы?

— Такташ...— диде Әхмәтсафа, көттереп кенә. Әле һаман колагында Мифтах хәлфәнең шелтәсе ишетелгән кебек иде: «Имансызланып йөрергә укыттыммы мин сезне? Шуңа өйрәттемме? Искелеккә каршы чыкканда, юлыгызда очраган һәрнәрсәне бетерегез, күмегез, яндырыгыз, дип үгетләдемме? Йә әйтегез, халыкның рәнҗеше, күз яшьләре өстендә яңаны төзеп булырмы? Һай, акылсызлар, башсызлар...»

— Такташ сезнең башларыгызны яхшы әйләндергән,— диде Муса, Әхмәтсафаны уйларыннан бүлеп.— Кызганыч, әсәрләрен газетлардан укысам да, үзе белән танышырга өлгермәдем. Мин Оренбурдан киткәндә, ул килеп җитмәгән иде булса кирәк; кабат килгәндә, ул юк иде инде. Такташ әлегә яңага хезмәт итми. Карт шагыйрьләр эзеннән бара,— дип, Такташны бик өнәп бетермәвен сиздерде Муса.— Бу хакта без Ченәкәй белән сөйләшкән идек. Ул да шушы фикердә.— Ченәкәй Оренбурда билгеле шагыйрь. Күпләр аны зур шагыйрьгә саныйлар. Тик нигәдер Ченәкәй, һәр кичәдә дип әйтерлек җиленүле чыгышлар ясап та, студентлар каршында артык абруй казана алмый. Такташ катнашкан бер кичәдә чыгыш ясап янды ул, шул чагында абруена көя төште. Шуннан бирле Такташны сөйми. Күрәсең, Такташны өнәп бетермәвен Мусага да әйтеп өлгергән. Алар дуслар булса кирәк. Мусаның сүз сөреше үк Ченәкәйне хәтерләтә.— Газраилләр, пәйгамбәрләр, Кабил, Һавил, күкләр, патшалар... Таң кызлары... Юк, безнең өчен түгел болар! — дип кистереп үк әйтеп ташлады Муса.

Әхмәтсафа, Мусаның Такташка ябырылуын килештерми, аңа каршы төшәсе итте.

— Такташны яраталар. Бигрәк тә яшьләр ярата... Шигырьләре дә әйбәт.

Мусаның бәхәскә керергә исәбе юк иде. Әхмәтсафа белән икесе арасындагы киеренкелек йомшарырга өлгермәде, тагын бәхәсле мәсьәләгә килеп төртелделәр. Ул хәрби-сәяси курсларда укыган чакта бирелгән ярыйсы ук таушалган шинелен киеп чыгып китәргә җыена башлады. Шулай да, әңгәмәгә ноктаны үзе куярга тиешлеген искәрткән шикелле, акыл сатып алды:

— Көрәш, бәхет җырлары кирәк безгә. Яшьләрне шул рухта тәрбияләү лазем, Әхмәтсафа дустым. Эшчеләр сыйныфына хезмәт итәрлек әдәбият тудырырга тиешбез. Менә кайда ул безнең юл! Яшьләрне революцион романтикадан биздерү җинаятькә тиң. Утны су белән кушып булмаган кебек, иске вәзен, өслүб, мәүзугъ та чүпкә очарга тиеш. Идея саташуларыннан туктарга вакыт, дускай...— Ул, сүзләренең башкаларга никадәр көчле тәэсир итүен тойган хәлдә, чыгу ягына борылды.— Мин бүгеннән Ченәкәй фатирында тора башлыйм. Мохтаҗлык кичерүче булса, ятакны башка бирәүгә дә бирергә рөхсәт,— дип, авыр адымнар белән ишеккә табан атлады. Авыруыннан һаман терелеп җитә алмавы хак иде Мусаның.

— Ченәкәй белән яшәргә була. Ул хәзер ашханә мөдире. Акмаса да тама,— диде Фатыйх Сәгыйтов. Нинди сәбәп аркасында моңарчы бәхәскә кушылмый торгандыр, үзе дә аңлап җитми иде бугай, үкенгәндәй, Муса артыннан сөйләнеп калды.— Бу мәхлук үзен зур шагыйрьгә саный инде. Кеше күзенә күренә белә. Әле күптән түгел «Авыру комсомолец» шигырен губком съездында сөйләп уңыш казанган. Хәзер күкнең җиденче катында йөри. Егет дөрес әйтте: ялан саен сәхнәгә сикереп менеп, иске шагыйрьләрнең әсәрләрен сөйләргә маташу — сәяси сукырлыкка тиң.— Ул Әхмәтсафага төртмәле караш ташлады. Фатыйх үзе кичәләрдә чыгыш ясамый, башка чаралардан да читтәрәк йөрергә тырыша. Ә инде эшкә йомгак ясаганда, иң беренче чәчрәп чыгып, башкалар өстенә тәнкыйть уты яудыручы ул иде. Мондый чакта аны тыям димә. Аны хуплап сүзгә Мәҗит кушыла. Әлеге ике тәнкыйть остасы эшкә керешсә, эһ тә итми, теләсә нинди җыелышның астын өскә китереп ташлыйлар. Бу ике көч бергә кушылса, аларны җиңү турында уйлама да. Хакмы, нахакмы — уйлап тормыйча, тәнкыйть корбаны өстенә кара түгәләр генә. Яңадан, аларның хаксыз икәнлеге ачыклангач та, кыенсыну, вөҗдан газабы кичерү юк. «Карга карганың күзен чукымый»,— дияләр дә, бетте-китте, вәссәлам шуның белән.

Шушы ике студент аркасында чак кына бәлагә тарымады Әхмәтсафа. Күңел түрендә утырган үпкә юшкыны әле кубып та төшмәгән, шуңа күрә ул Фатыйхның сүзләренә игътибар итмәгән сыман, үз эше белән мәшгуль булып, дәшми генә утыра бирде. Башкалар да сүзгә кушылмадылар.

...Американың ачларга ярдәм итүче җәмгыяте, башка күп төбәкләрдәге кебек үк, Оренбурда ашханә оештырды. Мөдир итеп Төхфәт Ченәкәйне билгеләп куйдылар. Шагыйрь буларак абруе артык зур булмаса да, яшьләр Ченәкәйне үз итәләр, очрашып, сөйләшеп йөриләр иде. Ашханәгә дә юл-

ны тиз таптылар алар. Мөдирнең вак-төяк йомышларын үтәп, бераз гына тамак ялгап алырга җай да чыккалый иде. Аны-сы өчен дә Ченәкәйгә мең рәхмәт яудыра студент халкы. Беркөнне Әхмәтсафаны чакыртып китерде Ченәкәй. Дәрес вакыты булса да (Гомәр агайның теге көнге сүзләре ярап куйды. Егет хәзер дәресләрне калдырмаска тырыша.), Ченәкәйнең гозерен аяк астына салып булмый, Заһид Шәркыйдан рөхсәт алып, китте мөдир янына. Эш хәйран гына буласы икән. Ашханә почмагына тау булып өелгән буш капчыкларны, ишегалдына алып чыгып, яхшылап он тузаныннан кагарга, дистәләп-дистәләп санап, яхшылап төреп куярга кирәк. Әхмәтсафа эшкә карусыз, җан-фәрман тотынды. Беренче капчыкны селкеп җибәрүгә, үзен он тузаны күмеп китте. Тирә-якта ак тузан өермәсе, егетнең башында бер фикер бөтерелә: капчыкларның һәркайсында аз гына булса да он калган икән, нигә аны болай исраф итәргә?.. Берәр җәймәгә сак кына кагып, җыеп алсаң, кич студентлар белән чумарлы аш пешерерлек он җыела түгелме соң? Һәм шулай эшләде дә.

Ул тулай торакка кайтып кергәндә, дәрес бетмәгән иде әле. Сыйныф кабинетлары суык булу сәбәпле, дәресләр тулай торак бүлмәсендәге почмакта үтә. Әхмәтсафа, башкаларның игътибарлы карашын күрмәмешкә салышып, үзенең караваты янына килеп чүмәште. Тумбочка эченнән күп укыдан таушалып беткән «Юксыллар сүзе» гәзитен алып идәнгә җәеп салды һәм бишмәт кесәсеннән, барсын да биһуш калдырып, ап-ак он бушата башлады. Сыйныфтагыларның укуда кайгысы китте. Һәркайсының миен бер сорау бораулый: бу кадәр онны каян, ничек юнәткән Әхмәтсафа?..

Егет үз эше белән мәшгуль. Күңеленнән Ченәкәйгә рәхмәт укый. Ул Әхмәтсафаның он җыеп мәшәләнгәнен күрмәмешкә салынды. Берәү булса, тавыш чыгарып та маташыр иде. Бер генә нәрсәне истән чыгарды Әхмәтсафа — Ченәкәй аны нәкъ менә шуның өчен дә чакырган иде. Егет намуслы, калдык онны тузанын да әрәм итми җыеп, тулай торактагы иптәшләре белән уртаклашуына иманы камил иде. Мондый эшне егеткә кушып ялгышмады. Каядыр барып килгәнче, егет аның әйтүен дә көтмичә эшкә керешкән иде инде... Әхмәтсафа ару белми тырышты. Капчык кагу тәмамлангач, караса, хәйран мая җыелган. Сөенә-сөенә ашханәдән иләк алып чыгып, җәймәдәге онны әйбәтләп иләп тә җибәрде. Капчык чүбеннән арынгач, кершән сыман он гына өелеп калды җәймәдә. Төрергә чүпрәк-мазар тапмый бәргәләнде, әмма озаклап эзләргә вакыт юк, бишмәт кесәсен каккалады да онны шунда тутырды. Кесә бушап калгач, Әхмәтсафа, гадәтенчә, ашыкмый гына гәзитне төреп, карават астыннан кечкенә сан-

дык тартып чыгарды. Онны шушы сандыкка салып, бикләп куйганчы сыйныфташларының күзе гел анда булды. Әйе, бу гамәлне барысы да күреп торды, Әхмәтсафаның исә аны яшерергә исәбе дә юк иде. Эшеннән соң, зур канәгатьләнү белән кулын чалбар балакларына сөрткәләп алган булды. Аннан зур эш кыруына тамчы да шикләнми, дәрес тыңларга үз урынына килеп утырды.

Бу араларда чит илләрдән килгән ярдәм хисабына студентларның ашавы бераз яхшыра төшкән иде. Әхмәтсафа сандыктагы онга әлегә кагылмаска, бар чагында бүредәй, юк чагында шүредәй кыланган студентларның ризыклары таки-токыга калганчы сабыр итәргә булды... Әмма беркөнне бүлмәдә шау-шу китте. Фатыйх Сәгыйтов белән Мәҗит, профком әгъзасы Әхмәтсафаны угрылыкта, ачлар өлешенә кул сузуда гаепләп, комсомол комитетына шикаять язып керткәннәр икән. Комитет мондый сигналны колак читеннән генә үткәреп җибәрә алмый, хәлнең чорына күрә гадәттән тыш булуын исәпкә алып, югарырак оешмаларга да хәбәр итеп өлгергән. Зур җыелыш уздырырга боерык бирделәр югарыдан. Көн тәртибендә бер генә мәсьәлә: «Әхмәтсафа Дәүләтъяровның җинаятен тикшерү».

Суыктан качып, җыелыш Әхмәтсафа яшәгән бүлмәдә үткәрелде. Аны алып баруны Фатыйх Исхаковка тапшырдылар. Ул, шикаятьне укып, аңлатма өчен сүзне Әхмәтсафага бирде. Бу хәлдән бөтенләй югалып калган егет кыюлыгын җуеп бетерә язган иде. Онның каян килеп чыгуын бәян итеп бетергәнче шабыр тиргә батты. Бүлмәдәш егетләрнең барысы да онның ни рәвешле Әхмәтсафаның кесәсенә «килеп кергәнен» беләләр иде, Сәгыйть Агишев, кушканны да көтеп тормыйча, онның һаман да сандыкта саклануын исбат итәргә теләгәндәй, йөгереп барып дустының карават астыннан теге сандыкны җилтерәтеп өстерәп чыгарды, ә дигәнче аны президиум өстәленә китереп куйды. Әхмәтсафага да җан иңде, сандыкны ачып, кечкенә төргәкне комитет әгъзалары алдына алып салды, аннан сак кына төргәкне сүтеп, өстәл уртасынарак шудырды:

— Сүз шушы он хакында бара. Угрылык турында исемә дә кереп чыкканы юк,— диде ул, акланырга теләп.— Егетләр белә: бергәләп тотарга иде исәп...

— Каргалыда туып-үс тә, угры да булма,— диде Мәҗит, тавышына үт ачысы чыгарып.— Гомер-гомергә угрылар оясы бит ул авыл.

Мәҗиткә кушылып Фатыйх Сәгыйтов та Әхмәтсафаны гаепләп маташты. Шушы ике студентка түбән сыйныфта укучы авылдашы Кәрим Хәрәмуллин да кушылды. Әхмәтсафа өчен сәере шунда, моны студентларның күпчелеге онытма-

гандыр — Кәрим институт баскычына аяк басуга кире борылып кайтып китәргә тиеш иде. Керү имтиханының беренчесен үк бирә алмады. Әхмәтсафага килеп ялынды. Аның тырышлыгы белән генә институтка кабул ителгән иде. Этне ияртсәң, сукма, ди, бүгенге көнгә кадәр Әхмәтсафа аны читкә какмый, үз энеседәй якын күреп, ярдәм итеп йөри иде. Тегесе дә шомарды, ни кирәк булса да, хәзер авылдашы янына йөгереп килеп җитә. Менә шушы Кәрим чәрелдек тавышы белән гаепләпме-гаепли Әхмәтсафаны:

— Дәүләтъяровлар гомер бакый ярлы кешенең канын эчтеләр Каргалыда. Сәүдәгәр нәселеннән ул. Әхмәтсафаның әтисе Мостафа да байбәтчә иде. Сәвит хөкүмәтенә байлыгын бирмәс өчен үз-үзенә кул салды.

Әхмәтсафаның йөзенә тимгелләр бәреп чыкты. Шушы минутта, әтисенә тел тигезгән өчен, Кәримне бугазлап атарга әзер иде. Әтисенең фаҗигале үлемендә үзен гаепле сизеп йөргәнлектән, аңа болай да авыр, җанында кузгалмас авыр таш яткан шикелле. Инде шушы хөрәсән, әти-әнисе олыгаеп барганда дөньяга килгәнгә авылда Бүлтерек кушаматы тагылган Кәримне мәңге гафу итмәсен тоеп, алга укталды.

— Яп авызыңны, Бүлтерек! — Әхмәтсафаны мондый ярсулы рәвештә күргәннәре юк иде, барысы да тынып калдылар.

Кәримнең генә туктарга исәбе юк иде, чәрелдәвен белде:

— Шулай инде ул, туры әйткән байбәтчәгә түгел, туганына да ярамый. Байлар алар хезмәтчеләрен изеп өйрәнгән. Хезмәтченең кулы сынса, җиң эчендә, башы ярылса, бүрек астында. Авыз ачып сүз әйтә алмый. Минем авызны томалый алмассың, Әхмәтсафа! Ул дәверләр үтте инде. Без ярлы-ябагайга көн килде, иптәш Ленин дилбегәне безнең кулга тоттырды. Без аны байбәтчәләр кулына бирмәбез!.. Бу алама студентның гаеп эшләрен саный башласаң, чәчләрегез үрә торыр, иптәш комитет әгъзалары. Он урлап, комсомол исеменә тап төшерде дип кенә уйласагыз, ялгышасыз. Комсомол билетын да саклый алмады ул. Үги инәсе мичкә якты билетын.— Кәрим әрсез карашын Әхмәтсафага төбәде.— Син нинди комсомол ди, билетыңны да саклый алмагач? Менә мин дә комсомол, билетым күкрәгемдә, йөрәк турымда йөри! — дип, Кәрим бишмәтенең түш кесәсеннән таныклык чыгарып, һавада болгап алды.— Чын комсомол шулай була ул! — Әхмәтсафа күреп алды, Кәрим урынына чүгүгә, янында утырган Мәҗит аның кулын кармап алып, нык кына кысып куйды. Тегесенең сөенечтән авызы колагына җитте.

Кәримнән соң сүзне Саттар алды.

Ул Әхмәтсафаны яклап бер сүз дә әйтеп тормады, чөнки аның өчен дустының гаепсезлеге ике икең — дүрт сыман,

Мостафа абзыйның вафатыннан соң Әхмәтсафаның нинди рухи газаплар кичерүен дә яхшы белә, комсомол билеты белән булган хәл дә күпләр өчен таныш, шуңа күрә ул Кәримгә төбәп сөйләде:

— Кәрим,— диде ул, ачулы тавыш белән,— әгәр син, тәмәке тартып маташкан булып, авылга ут салмасаң, бүген ул кадәр үк мохтаҗлык кичермәс иде Каргалы халкы. Мостафа абзыйга тел тигерү түгел, аның рухы алдында тезләнергә кирәк сиңа. Онытма, авыл дөрләп янганда, олы абзыйлар сине эләктереп алып, утка ыргытмакчы булганда, кем аралап алды үзеңне, ә? Әгәр Мостафа агай килеп җитешмәсә, синнән шул көндә көл-күмер генә кала иде.

Кәрим үзендә һичнинди гаеп күрми, урыныннан чәпчеп алды:

— Синең атаң эләктерде мине, ул башлады!..

Саттар сүзләрен теш арасыннан саркытып дәвам итте:

— Инде үткән җәй кем килеп егылды безнең мастерскойга? Үзегезнең янга алыгыз, ачтан үләбез, дип, кем ялынды? Барыбыз да каршы төшкәндә, кем сине яклады? Кем сине институтка укырга кертте?

— Харап икән...— диде Фатыйх Сәгыйтов.

Саттар китергән дәлилләр Әхмәтсафаның гаепсезлеген раславын күпләр шәйләп алган иде. Җыелыштагылар белән беррәттән, президиумдагылар да Кәрим ягына яндыргыч караш ташлап алгаладылар. Алар инде Әхмәтсафага теләктәшлек күрсәтеп утыруларын яшермиләр иде.

Сәгыйтов кына моның белән килешмәвен белдерде.

— Бер ярлы малайга ярдәм күрсәткән дә, хәзер Әхмәтсафа Дәүләтъяров судан ак, сөттән пакь булып калган икән. Ул, башкаларга ярдәм кулы сузган булып, иң беренче үз ягын кайгырта. Берәр гаеп эшләсә, аннан шуны калкан итеп куя. Бүгенге кебек...

— Миңа да аның ярдәме зур булды,— дип сикереп торды Зиннәт Әбдерәшитов.— Әхмәтсафа булмаса, ул укуда ярдәм итмәсә, мин бүгенге уку алдынгысы булмас идем, йә инде күптән институтны ташларга туры килер иде. Әхмәтсафа чын иптәш, чын дус ул!

Эшнең үз файдасына борыла төшүен тоеп, Әхмәтсафаның тамак төбен нидер яндырып алды, күзләре дымланды. Нахак эштә гаепләнгән чакта да болай ук җебемәгән иде, иптәшләре дәррәү күтәрелеп, яхшы гамәлләрен саный башлагач, бөтенләй күңеле сыпылып, түземлеге сизрәгән чүпрәккә әйләнеп бара түгелме соң? Ул, үз-үзен кулга алырга тырышып, урынында таптанып алды. Аның һаман гаепләнүче сыйфатында басып торуына эче пошып, Фатыйх Исхаков президиумдагыларга сорау бирде:

— Әллә иптәш Дәүләтъяровка утырырга рөхсәт итәбезме? Мәсьәлә ачык шикелле. Гаепләрлек хата эшләнмәгән. Шулай да, иптәш Дәүләтъяров, шул чакта барлык иптәшләреңә онны каян алуыңны әйтеп, аны олы сергә әйләндермәсәң, имеш-мимешкә юл калмас иде. Безгә шикаять кергән икән, аны тикшерми кала алмыйбыз. Һәр очракта дөрес карар кабул итеп, тиешле чарасын күрергә тиешбез,— дип, Әхмәтсафа урынына утырган арада, аклангандай сөйләнеп алды.

Әхмәтсафаны яклап Ченәкәй, Муса Җәлилов сөйләделәр.

Гайшә Мөхәммәдованың:

— Әгәр Әхмәтсафа булмаса, тараканнар шикелле катып үләдериек,— диюенә, күңелле генә көлешеп тә алдылар. Шунысы ачык, Әхмәтсафа Дәүләтъяров, үзе дә сизмәстән, күпләр алдында абруйлы иптәшкә әверелгән, күпләргә ярдәм кулы сузарга өлгергән иде инде.

Гаҗәпләндергәне шул булды: җыелыш беткәч, аның янына Кәрим килде. Буржуйка дип аталган тимер мич тирәсендә күп маташкангадыр инде, күмер-көл тузанына баткан, каралып беткән кулын Әхмәтсафага сузды:

— Иптәшләрнең сине яклап, хатадан аралап алуларына сөенеп утырдым. Алгы көннәрдә мондый хәлләргә төшмә инде, парин. Авылдашыңны тикшерә башласалар, бигрәк кыен икән,— дип сөйләнгән була үзе. Әйтерсең җыелыш Әхмәтсафаны гаепсез дип тапмаган, аны акламаган, фәкать кайбер студентларның яклаулары аркасында гына Әхмәтсафа җәзадан котылып калган. Кәримнең тел төбендә шушы фикер ярылып ята иде.

Әхмәтсафа Кәрим Хәрәмуллинның кыланмышына үртәлеп бетсә дә, аның бу гамәлен тулысынча бәяләп бетерерлек хәлдә түгел иде. Алда әйтелгәнчә, шактый хисләнеп тә киткән иде егет, шуңа күрәдер Кәримнең үзенә сузылган кулына бармак очын тигереп алды. Саттар белән Муса аны көтеп торалар иде, ашыгып алар янына китеп барды. Тегеләре исә, ул килеп җитүгә, аны ике яктан култыклап алдылар. Муса нидер сөйләп, Әхмәтсафаны тынычландырырга тырышмакчы иде, Саттар Әхмәтсафаның Кәримгә кул биреп торуын килештерми шелтәләп алды:

— Беркатлы булма инде, Әхмәтсафа. Шул Бүлтереккә кул биреп торасың. Бер саткан кеше мәңге сатачак, дустым. Бүгеннән мин аңа тамчы да ышанмыйм.

— Достоевскийның князь Мышкины сыман тотабыз шул без үзебезне...— диде Әхмәтсафа, уйлана төшеп.— Кәрим кебекләр беркайчан да игелекнең кадерен белмәячәкләр, аларның үз туксаны туксан. Андыйлар башкаларны ишетү түгел, үз күңелләрен дә тыңлап азапланмыйлар. Җаннары пычранган саен, үзләрен дөньяда ышанычлы тоталар бит алар.

Ә без һаман яхшылыкка, яктылыкка омтылабыз. Шулай гына яши алабыз. Тормыш кануннары кырыс, күңелләрендә мәрхәмәт тулып ашкан кешеләрне бөтереп кенә ала да кирәгенчә файдалана, кирәге юк дип тапкач, таптый, сыта, изә. Болар Гомәр агайның сүзләре иде...

— Шулай да шат мин,— диде Муса җилкенеп.— Бүген ялганга, явызлыкка каршы тора алуыбызны күрсәттек бит. Димәк, көч, хаклык безнең якта. Әгәр дә Кәримгә, аны котыртучыларга үч саклап, яңа җәнҗаллар чыгарып йөрсәк, акылны, җегәрне юкка сарыф итү генә булыр иде. Әхмәтсафа бик матур фикер әйтте. Без йөрәк тавышына колак салырга өйрәнергә тиешбез. Достоевскийны мин дә укыдым. «Акыллы булып та, башкаларга йөрәк җылысын бирүдән баш тарткан адәм, башкаларга йөрәген туктаусыз тәкъдим итеп йөргән акылсыз кешегә тиң», дигән бугай ул. Мондый типларның һәр икесе чын кеше булудан ерак тора. Кылган гамәлләребез кешелекле булсын, дусларым. Әхмәтсафа шул юлны сайлаган икән, безнең аны шелтәләргә хакыбыз юк...

* * *

Күңел төшереп, кул кушырып утыра торган чак түгел. Ашханәдә көнгә бер мәртәбә тамак туклыгы итеп ала да, җан асрау ягын кайгыртырга керешә. Егет йә вагон бушатучы йөкчеләргә булышып икмәк таба, йә калада үз йортлары белән гомер кичерүчеләр ягына китеп бара. Һәр йортта булмаса да, кемдәдер нинди дә булса бер эш табыла. Эше булса — ашы бар, шулай үз көче белән тамак туйдырып көн үткәрә ул. Җан рәхәте. Башка бер генә дә кичәгә катнашмам, дип ант иткәне дә бар. Тик янына Муса килсә, хәлне үзенчә бора да куя. Эч серләрен ачкан булып, сөйләндереп-көлдереп, ныклап бикләп куйган җанына ачкыч ярата, ул да булмый, тагын бер кичә оештырырга җыенуы хакында хәбәр итеп ташлый. Кай арада теге анты исеннән чыгып өлгергән, Әхмәтсафа сизми дә кала, дустына булышлык күрсәтергә ризалык бирә. Хәер, Әхмәтсафа кичәләрне үзе дә көтеп кенә тора. Муса булган җирдә Гайшә була тек була инде, Гайшә булса — Заһидә килми калмый.

Заһидә... Озынчарак аксыл йөзле, үз уйларына бикләнеп йөрергә ярата торган кыз Әхмәтсафаның бөтен күңелен биләп алды шул. Әгәр, Заһидә җир читендә берәр кичәдә катнаша дисәләр, Әхмәтсафа шунда барып җитәргә дә әзер. Репетиция вакытларында Заһидә дөньясын онытып шаяра, көлә, бөтенләй ачылып китә. Андый чакта Әхмәтсафа чибәр кыздан күзен алмый, сихерләнгән сыман, гел аңа карап тора. Кызның ачлы-туклы яшәүдән сулыгып калган йөзенә сизе-

лер-сизелмәс алсулык та җәелә, күзләрендә очкын кабына. Ара-тирә егет ягына яндыргыч караш ташлап та алгалый. Һәй, ул карашларның бәгырьләрне яндырып, өтеп, җанны чеметтереп алулары! Шушы бер караш өчен гомереңне бирерсең, билләһи. Әхмәтсафаның үзенә битараф булмавын белә Заһидә. Кайбер чакларда икесенең карашлары очраша. Бүлмә ничек суык булмасын, егетнең борын очына тир бәреп чыга, кыз шундук керфеген түбән төшерә, йөзен читкә бора, йә, юк сәбәп табып, Гайшәгә яки Пәрвазга, һич тә булмаса, музыкант кыз Мөгыйнәгә бәйләнгән була башлый. Әхмәтсафаның исә йөрәгенә ут үрли, бөтен тәне кызыша, тиз генә Заһидәнең арык кулларын үзенең учына аласы, кайнар тыны белән җылытасы килә. Мизгел эчендә хыялы күккә чөелә, чәчәк ата, җимешләнергә дә өлгерә. Хыялы чынга күчсә, кызның озын керфекләре арасына яшеренгән коңгырт күзләренә текәлеп озак, бик озак карап торыр иде ул, башында бөтерелеп тә, әле теле белән бер мәртәбә дә әйтеп карамаган әллә нинди назлы сүзләр пышылдар иде.... Хыял кысыр өмет кенә булып ала шул. Кичәләр үтә дә китә, әйтеләсе сүзләргә чират җитми кала. Институт коридорында кара-каршы очрашсалар, Заһидәне алыштырып куйганнармыни — күрсә дә күрмәмешкә сабышыр, сүз катсаң, мәңге җавап кайтармас. Боек күңелле, сәер табигатьле бер кызга әйләнә дә куя. Әйтерсең кичә генә бер сәхнәдә янәшә тормаганнар, шаян такмаклар әйтешеп, тамашачыларны көлдермәгәннәр, җитәкләшеп пәрдә артына кереп китмәгәннәр, тынмас алкышлар астында кабат чыгып, куллары кулда килеш тамашачыларга килештереп баш иеп тормаганнар. Кызып китү генә булды микәнни?.. Барысы җилгә очканмыни соң?! Кызның, онытылып китеп, сәхнә артында бермәл үзенә сыенып торуы да әкият яки төш кенәмени?.. Юк, төш түгел, өн иде бит. Тәненең кайнарлыгы егетнең күкрәген һаман яндырып торган сыман югыйсә.

Бүген инде Заһидә башка кыз. Башка кыз дию дөрес тә булмас, үз эзенә төшкән, кире үз халәтенә кайткан дисәң, хак булыр. Ул —Такташ белән саташкан. Ул — мәхәббәт колы. Ул — җавапсыз мәхәббәте белән бәхетле. Кыз әле һаман да зәңгәр күзле шагыйрь егетнең каладан тиз генә, көтмәгәндә генә китеп баруын һичничек башына сыйдыра алмый. Кайсы тарафларга китеп югалганын белсә, Такташ янына кош сыман очып китәргә әзер самими җанлы, үз хисләре, үз уйлары белән яшәүче шигъри күңелле кызга әйләнә дә куя. Кызның күңелендәге яшьлек үҗәтлеге тудырган хыял белән өретелгән хис-уйларын куып чыгарып, аны үзенеке генә итә алмавына Әхмәтсафа аз газапланмый. Тик ничек, ни рәвешле кызның күңелен яулап алырга? Монысына ул һичбер җавап таба алмый. Ике арада Такташ дигән кыя тора шул,

аны алып ташларга егетнең кодрәтеннән килми. Моны ул үзе дә, Заһидә дә яхшы төшенделәр булса кирәк. Мәхәббәт — пар канатлы булса гына мәхәббәт! Гашыйкларны ике канатында биек зәңгәр күкләргә күтәреп, әллә кайларга, җан ашкынган бәхет утравына алып китәргә сәләтле булмагач, нинди мәхәббәт булсын инде ул... Сыңар канатлы мәхәббәт кызганыч шул, бик кызганыч. Оясын давыл туздырган, канатын кыяга бәреп имгәткән бөркетне генә күз алдыгызга китереп карагыз — Әхмәтсафаның хәле шул бөркетнекеннән җиңелрәк дисезме?.. Сөю газабын ул яшерен генә, беркемгә сиздермәскә тырышып, ялгызы гына кичерә. Ни хәл итәсең? Беренче мәхәббәт, диләр шул аны. Егет йөрәк мәсьәләсендә бөтенләй тәҗрибәсез. Укуда, хуҗалык эшләрендә күрсәткән елгырлыгын, тапкырлыгын һәм чырышлыгын бу өлкәгә дә күчерә алса, кем белә, бәлки, Заһидәнең йөрәген яулап алырга мөмкин дә булыр иде. Әмма егетнең күңеленә кем тарафыннан, кайчандыр әйтелгән, диндә вә мәхәббәттә көчләү юк, дигән сүзләр ныклап кереп утырганнар. Белә бит инде, бер генә халык та бер генә динне дә яуларсыз, көрәшләрсез кабул итмәгән. Хак мәхәббәткә ия буласың килә икән, күз ташларга иренмә — әнә Гаяз Исхакый хәзрәтләре: «Тартышуда гына табарсың үз хакыңны!» — дип, акка кара белән язып куйган. Ни хәл итәсең, егет мәхәббәт өчен даулашырга әзер түгел иде әле. Бар күңелен, җанын мәхәббәт итеп Такташка салган кызны хыялый уйлардан аралап алырга көчсез, чарасыз иде ул.

Ә Мусага нәрсә? Аның Гайшә белән борчагы пешә. Кичәләргә дә рәхәтләнеп бергә йөриләр, институтта очрашсалар, авыз авызда, каян сүз табып бетерә торганнардыр, Әхмәтсафа исе китә — ничек шулай кызлар белән озаклап-озаклап, тәмләп сөйләшергә мөмкин? Хәер, Муса сөйләргә оста инде анысы, үзен тыңлаучы гына булсын. Шуңа күрәдерме дус итеп йөргән сабакташларыннан берәү каядыр барырга җыенса һәм моны Муса белеп алса, тегесе Муса белән барырга атлыгып торамы-юкмы — анысы артык әһәмиятле түгел, сабый баладай күзләрен мөлдерәтеп:

— Дускай, мине дә алып бар әле!.. — дип әйткәнен әллә тагын үзе сизми дә кала. Аннан бу үтенеченең бик тә мөһим берәр вакыйгага бәйләнгәнен искәрткән сыман өстәп тә куя. — Ул якларда күптән булганым юк... — Әгәр барасы җир якын, көн саен үтеп-сүтеп йөргән юл өсте булса, Муса монда да җай таба, ияреп бару теләген кире кагасы түгел: — Бергәләп урам һавасын сулап, сөйләшеп барырбыз... — ди.

Үзе яшәгән фатирга да кунаклар алып кайтырга ярата ул. Тулай торактан киткәч, шагыйрь һәм укытучы Төхфәт Ченәкәй торган ярым җир астындагы бүлмәгә күчкән иде

Муса. Ченәкәй кызганып үзе чакырып китергән иде, ахры. Бүлмә дисәң, хәтерең калыр, подвал инде шунда. Менә шул подвалга көн дә кемнедер ияртеп кайтып керә ул. Моңа Ченәкәй артык ачуланмый бугай, шуңа күрә Муса үзен хуҗаларча тота, каралып беткән чәйнекне тимер мичкә кайнатырга утырта. Су шаулап чыккач, калай кружкадан авызларны пешерә-пешерә («чәй» дип атасаң, бик үк дөрес булмас) сыек сары су шопыралар. Кайчакта, кунагына карап, Ченәкәй үзенең «запас»ын — ипи кисәкләрен дә чыгара. Әхмәтсафаны Ченәкәй нигәдер үз итте, шуңа мондый сый еш эләгә иде.

Мусаны тыңлап баруы рәхәт. Урамга аяк басуга, сүзгә керешә. Сөйләгәннәрен тыңласаң, исең китәр, әллә тагын илле ел гомер сөргән, дөньялар гизгән ил агасы! Кисәктән каршыларына суыктан бөрешеп, йөгерә-атлый килүче кыз-кыркын килеп чыкса, Муса, шып туктап, Әхмәтсафаны җиңеннән эләктереп ала һәм аңа акыл бирә башлый:

— Кызларны күрсәгез, ди Ченәкәй, һич кенә дә битараф үткәреп җибәрмәгез, ди. Туктап, йөзенә карагыз, йөзен күрергә тырышыгыз, ди. Йөзен күрсәтмәсә, берәр чарасын табарга тырышыгыз — йә сүз катыгыз, сак кына этеп җибәрегез, ди. Артыннан да карап калыгыз: гәүдәләре ничек, атлаулары килешлеме? Һәр кызның үзенә генә хас сөйкемле чалымнары була икән. Ченәкәй белми әйтми, кызлар мәсьәләсендә профессор дисәң дә була. Ул миңа әйтте, мин сиңа тапшырам. Зиһен сандыгыңа салып куярга тырыш син, егет. Бу дөньяга ике килмәгән лә... Кызлар үзләренә игътибар иткәнне бик яраталар, ә син... — дип, Әхмәтсафага җиңелчә генә төртеп ала Муса. — Заһидә, дип, кибеп-корып, озакламый аяк та сузарсың әле. Заһидә шәп кыз, борчагың пешми икән, акылыңны җуйма. Кызлар күп булыр ул, ә син берәү генә, һәркайсы өчен акылдан калсаң... Кызлар мәсьәләсендә балыкчыдан үрнәк алу кирәк, дустым. Кармак сал да тартып ал. Эләксә — балык синеке, эләкмәсә — хафаланып утырма, кармагыңны җый да башка күлгә күч... — Муса шундый оста сөйли, Әхмәтсафа ышанмый тора: Муса үз сүзен сөйлиме, әллә кызлар хакында аңа Ченәкәй шулкадәр «дәрес»ләр биреп өлгергән?! Сөйләвенә караганда, инде Муса өчен бу мәсьәләдә бернинди сер юк, аны берничек эздән чыгара алмассың. Гайшә белән сөйләшкәндә дә, Ченәкәй биргән сабакны истән чыгармый гына сөйләшә микән? Алай булса... Кая йөрәк, иң кадерле хисләр кая? Чын күңелдән кызлар белән сер уртаклашмагач соң. Муса әйткәнчә, кармак салып йөрүче генә булсаң, алдашу килеп чыга түгелме?.. Юк, Муса шаярта гына торгандыр, Заһидә белән уртак тел таба алмавыннан, кыюлыгын җиңеп, кыз белән ачыктан-ачык сөйләшергә батырчылык итмәвеннән көлеп кенә сөйли бугай ул.

...Бүген дә шулай Мусаны тыңлый-тыңлый фатирларына килеп керергә өлгермәделәр, Ченәкәй, яткан урыныннан сикереп торып, сәер хәлдә бүлмә буйлап йөренә башлады. Бүлмә салкынча, Ченәкәйнең иңендә озын шинель, аягында иске штиблет ботинкалар. Ул өстәлдәге калай чәйнектән кружкага су агызып шопырдатып эчте дә, караватта янәшә утырган Муса белән Әхмәтсафага игътибар да итмәгән сыман, әрнүле тавыш белән шигырь укый башлады:

Инде үтсен тормышымның төннәре, кыш көннәре,
Инде гомеремнең кояшлы нурлы язын каршылыйм.
Күзләремнән нур түгелсен, сүзләремнән энҗеләр,
Мин дә балкыйм, нурланыйм бер — көн булыйм, бер яктырыйм...

Муса, өстен салып, чөйгә элеп куйды. Әхмәтсафа да, караватта утыруын килештермичә, пәлтәсен мыштым гына салып, ишек катындагы букәнгә чүмәште.

Төхфәт Ченәкәй — озынча йөзле, кыска иякле, киң маңгайлы чибәр генә кеше иде. Озын, нечкә муенына җитү чәчле зур гына башны тотып тору җиңел түгел иде бугай, Ченәкәй, башын түбән иеп, эре-эре атлап бүлмә буйлап тагын бер әйләнде дә моңарчы җанында йөргән авыр уйларын берьюлы тышка бәреп чыгаргандай иңрәп алды:

— Бармы дөньяда бәхет, егеткәйләрем? Бармы дөньяда безне аңлаучылар? Җир астында сөрсеп ятудан кайчан туктарбыз да, якты дөньяга кайчан чыгарбыз без? — Ченәкәйнең күңеле төшенке чакларда кабатларга ярата торган әлеге сүзләрен Әхмәтсафа бер генә ишетмәде инде.

Бу сүзләр Мусага да яхшы таныш. Ул, үзенә хас акыл бирүчән тавыш белән, Төхфәт абыйсын тынычландырырга керешге:

— Килер, Төхфәт абый, килер ул вакытлар. Кояш чыгар безнең баш өстендә. Көннәр җылыныр, агачлар яшәрер, орлыклар шытар. Без яшәргә килгәнбез, ирек кояшы үзенекен итәчәк, салкын кыш үтәчәк ул, үтәчәк.

Төхфәт Ченәкәй кашларын җыерып торды да, көлемсерәп, Мусага карап алды. Аннан карашын аның юлдашына күчерде:

— Ирек дисез инде ә?.. Бәхетле булу өчен күпме ирек кирәк кешегә, уйлап караганыгыз бармы?

Бу сүзләрнең үзенә төбәлгәнен аңлап алган Әхмәтсафа юаш кына тамак кырды.

— Ирек, хөрлекне бизмәнгә салып үлчәп, күпме кирәк, шуның кадәр алып буламыни инде. Кануннар тәэмин итәргә тиеш шәхес ирегең...

Ченәкәй, мыскыллы елмаеп, түшәмгә бакты.

— Һи-и, егеткәем!.. Кануннарны кем чыгара соң безнең

дәүләттә? Җыен жулик, төрмә былбылы, шымчы-җәсуслар хакимлектә... Без исә, шул кануннарның колы булып, салкын подвалда кандала туйдырып ятабыз. Ирекнең тәмен яхшы татыйбыз. Ха-ха!..

— Ирекнең чиге юк! — диде Муса, белдекле тавыш белән. Төхфәт абыйсы белән бәхәсләшергә, үз уйларын ачыктан-ачык әйтергә шүрләми иде ул. Аңа Оренбурда Төхфәт Ченәкәйдән якын кеше юк. Чибәр, буй-сынына тел-теш тидерерлек түгел Төхфәт абыйсы аны ач үлемнән йолып калды. Мусаның язган һәр шигыре өчен сөенеп, аңа дәрт һәм куәт биреп торучы, иренмичә, әдәбиятта бар белгәнен шәкертенә тапшыручы — язу осталыгына өйрәтүче остаз да. Турысын әйтергә кирәк, Муса өчен Төхфәт Ченәкәй әтисе кебек якын бер кешегә әйләнгән мәрхәмәтле зат иде.— Чикләүләрне бетерү өчен төзелә яңа дөнья. Тартышлар аша без чын ирекkә киләчәкбез. Кан коелыр, җан кыелыр, әмма көрәшчеләр тоткан юлларыннан чигенмәсләр, шул чагында без чын ирекнең ни-нәрсә икәнен белербез. Әлегә безнең бүгенге хәлне күздән кичерсәк, бу сүзләр көлке тоелыр, билгеле... Әмма хаклык кояшы чыкты инде. Бу салкын кышның гомере озын калмады. Ирек маршын җырлап азат көннәргә барачакбыз әле, барачакбыз Төхфәт абый.

— Бирсен Ходай! — диде Төхфәт, баягы ярсуыннан сүрелә төшеп. Мусага каршы килеп, аның өметен кисәсе килми иде, ахры. Шулай да көтмәгәндә башланып киткән бәхәс үзенә дә кызык тоелды, дәвам итәсе килде: — Уйлап караганыгыз бармы, ни өчендер «ирек» дигәч, кешеләрнең йөзләре яктырып, иреннәренә елмаю куна,— диде ул. Мусаның хисләреннән айный алмый торуын күреп, төбәп аңа сүз катты.— Менә син, Муса, үзең сөйлисең, ә эчеңдә ниндидер шайтан бар шикелле, гел кытыклап кына тора кебек. «Ирек» дигәндә, уйныйсың килә, шаярасың килә, мәтәлчек атасың килә, җанда гына түгел, акылда да җиңеләю тоела. Бәс, шулай булгач, бу сүзнең асыл мәгънәсе астында көлкеле хыялый бер җилкенү — ирония ята түгелме соң? Соңгы вакытта миңа шулай тоела башлады,— диде дә янә шигырь юлларына күчте:

Гөлләр елмайган, кырлар нурланган,
Бөтен җир-күге нурга чорналган...
Шашам, ашкынам... Шатланам чиксез,
Азат мин, азат! Бәхетем офыксыз!..

Шигырь Әхмәтсафага таныш, ул — Бабичның «Бәхетем» шигыре иде.

— Аһ, Бабич, җан дустым! — диде Төхфәт абый. Күзләрендә яшь күренде аның.— Кая син, нигә килеп кермисең дөньямны нурландырып. Кайсы иблиснең кулы күтәрелде

сиңа, кемнәр һәлак итте сине,— дип өзгәләнде ул. Караватына утырды да, башын ике кулы белән кочып, сүзсез калды.

Әхмәтсафага нигәдер күңелсез булып китте, тыны кысыла башлады, ул чыгу ягына кузгалды.

* * *

Ашханәдән чыгып, ашыга-ашыга тулай торакка күтәрелгәндә, Әхмәтсафаны Мусаның көр тавышы туктатты.

— Дустым, кая чабасың, куып җитеп булмый,— диде ул. Әхмәтсафаның артыннан әллә чыннан да шактый йөгергән, еш-еш сулыш ала, шулай да күзләрендә көләч чаткылар уйный.— Бүген балалар йортында кич утыру була. Шәриф ага Камал Салих Сәйдәшне музыка уйнарга чакырган...— Муса, мөһим хәбәр әйттем, инде үзең хәл ит дигәндәй, беркавым сүзсез торды.

— Кем әйтте? — диде Әхмәтсафа, аптырый төшеп. Тагын бер баскыч өскә күтәрелде.— Әллә кайларда, әллә нәрсәләр була торгандыр инде, дускай,— диде, Мусаның тел төбен аңлап бетермәвенә ишарә итеп.

— Ченәкәй әйтте,— дип, Муса, гадәттәгечә, аның җиңен тартып куйды.— Әйдә, без дә барабыз. Үземә генә күңелсез булыр өлкәннәр арасында. Икәү булсак...

— Безне анда чакыручы юк бит? — диде Әхмәтсафа, чакырусыз-нисез олуг әдип Шәриф Камал каршысына килеп басуларын күз алдына китереп. Аннан ул Салих Сәйдәшевны күргәне булса да, аның белән бөтенләй таныш түгел. Белгәне шул: Салих Сәйдәшев музыка мәктәбе директоры, музыка мәктәбе укучылары студентлар кичәсендә катнашса, иң алгы рәттә Сәйдәш тә (музыка мәктәбе шәкертләре яратып, аны «Сәйдәш» дип кенә атап йөртәләр иде) була. Музыка тактына башын кагып алулары, шәкертләре уйнаганда төгәлсезлек китсә, кинәт кулларын җәеп, уңайсызланган шикелле көлемсерәп куюын да күргәне бар, тик болай, Муса әйтте дип кенә, ул катнашкан кичәгә барып керү...

Ул, сәбәп табылганга куанып, Муса тәкъдименә каршы төште:

— «Орлес»ка чакыралар бүген. Эшче куллар җитми икән, булышуыбызны сорадылар.

Мусаның Әхмәтсафа белән дә, башкалар белән дә «Орлес»ка — Оренбур агач яру заводына берничә мәртәбә барганы бар. Эшкә дисәң, җебеп тора торганнардан түгел, башкаларга салынмый, иренми, тирләп-пешеп, янып эшли. Егетнең бу сыйфаты бары тик мактауга лаек. Кайбер чакта Әхмәтсафа жәлләп тә куя аны: арык кына, үсмерлектән яңа чыгып килүче егет кисәге, кайда нинди чара үткәрелсә, шунда катнашырга тырыша; барысына өлгерергә омтыла,

укуда булсын, эштә булсын, һич кенә сынатасы килми; ниндидер серле көчләр йөрткән сыман тоела үзен. Менә хәзер дә, Әхмәтсафаның «Орлес»ка барырга җыенуын белгәч, Муса, керфек кагып алганчы, бүгенге кичнең планын «төзеп» тә куйды:

— Бик яхшы, дустым,— диде ул, тавышында канәгатьләнү төсмере дә чагылып китте.— Иң элек бергәләп балалар йортына кереп чыгарбыз. Мин анда «Авыру комсомолец» шигырен укып алырмын, син балаларга гимнастик күнегүләр ясап күрсәтерсең. Шәриф абый бик яратып карый синең кыланганнарны. Күрерсең, безнең чыгышларны ошатып кабул итәчәкләр,— диде Әхмәтсафага кире чигенер урын калдырмыйча.— Аннан «Орлес»ка китәбез...— Сер әйткәндәй, тавышын баса төшеп өстәп тә куйды.— Мин «Орлес» заводына багышлап поэма язарга йөрим әле, дустым. Башымда материал бар да сыман, шулай да утырып язарга әзерлек җитми кебек.

Оренбурда эре завод-фабрикалар юк дәрәҗәдә. «Орлес» — алар арасында иң зурларыннан санала иде, шушы завод хакында Мусаның поэма язарга җыенуы Әхмәтсафага яңалык, күңелле яңалык иде. Ул, Мусаның ниятен хуплавын белдереп, шагыйрь дустын кочаклап ук алды һәм алар, күңелле сөйләшә-сөйләшә, тулай торакка табан атладылар. Мусаның, бернинди кыенлыклар алдында җебеп төшми, һаман яктылыкка, иҗатка омтылуы һәркемдә ихтирам уятырлык иде.

...Муса суга караган тылсымчы шикелле булды: балалар йорты директоры Шәриф Камал аларны сөенеп каршы алды. Алар кичә барган бүлмәгә сак кына кереп, урыннарын алырга өлгермәделәр, Шәриф абый Мусаның колагына иелеп, программага алар килү сәбәпле, үзгәрешләр кертүен әйтте. Әхмәтсафага карап елмаеп алды.

— Бу егет тә күнегүләр ясар бит инде,— диде ул.— Мондагы балалар күргән нәрсә түгел, бәлки, егеттән үрнәк алып, үзләре маймыллана башларлар.— Тыенкы гына көлеп куйды балалар йорты директоры.— Әле Сәйдәш уйный, аннан Ченәкәйнең шигырьләрен тыңлыйбыз, аннан Мәҗит тә чыгыш ясап алыр...— дип, ул алгы рәткә үз урынына китте.

Мәҗит Илдар — Оренбурның шөһрәтле артисты икәнен яхшы белә Әхмәтсафа. Мондый кешеләр янында чыгыш ясап, хур булып бетмәсәләр ярый инде.

Әхмәтсафа, игътибар белән сәхнәдә, бераз гына залдан күтәренке итеп эшләнгән төштә, пианино уйнаучы чибәр кешегә карап алды. Тамашачылар музыка авазлары тәэсирендә иде, шылт итүче юк. Барысы да шушы гаять чибәр кешенең пианино клавишлары өстендә үтә бер җиңеллек белән йөгерүче аксыл, нәфис бармакларына бакканнар да, сокла-

нудан авызларын ачып, тып-тын калганнар. Әхмәтсафа да таң калды. Уйнаучының бармак хәрәкәтләрен ул җәйге матур иртәдә, назлы җил иркендә Сакмар суында вак-вак дулкыннарның, бер-берсен куышып, якты кояш нурларында уйнап-шаярып йөгерешкәненә генә тиңли ала иде. Бүлмәдәге һәркем — музыка әсире... Әхмәтсафа моңарчы ишетмәгән әллә нинди серле көй уйный иде Сәйдәш абый. Озын коңгырт чәчләре маңгаена сибелеп төшә дигәндә генә, ул башын артка чөеп ала. Мондый чакта аның йөзендә сизелер-сизелмәс уйнаган сихри нурлар, чәчләренең тыңлаусыз дулкынлануы да, гәүдәсенең музыка көенә тирбәлеп-сыгылып алуларына кадәр Такташны хәтерләтә иде. Хәтта күзләренең зәңгәрлеге дә тач Такташныкы. Бермәл, онытылып китеп, пианино янында Заһидә басып торган сыман да хис итте егет...

Заһидә исенә төшкәч, музыкант, ул уйнаган көйләр тагын да тәэсирлерәк тоелды. Заһидәне үзләре белән чакырмавына үкенеп тә куйды. Югыйсә каршы очраган иде бит кыз, алар Муса белән кичәгә җыенып чыгып барганда. Хәтта ки, Мусаның шаяртып нидер әйтүенә колак салмастан, Әхмәтсафага карап сүз катмакчы да булган иде. Егетнең, әллә бик тә мөһим эшкә соңга калудан курыккан сыман ашыгуданмы, әллә җавапсыз мәхәббәттән исәнгерәп йөрүенә чик куярга теләпме, кызга артык игътибар итмәстән, тәкәллефсез генә үз яныннан горур гына үтеп баруын күреп алгач, дәшми калган иде. «Их!» дип, янә бер сызланды Әхмәтсафа. Азга гына тукталган булып, бер-ике кәлимә сүз әйтешеп алсалар, ни булыр иде?! «Әйдә!» дисә, бәлки, килгән дә булыр иде. Шушы музыканы тыңлап, күңеле юаныр, боек җаны ачылып китәр иде. Бәлки, шушы кичә, нәкъ бүгенге кичә бер-берсенең күңеленә ачкыч табарга ярдәм итәр иде. Егет дөрестән дә кызның үзенә булган салкын карашын һаман үзгәртми йөрүенә үпкәли дә башлаган иде бугай инде, шул үпкәләвен җиңеп, бүген кызга дәшсә, дөньялар бөтенләй икенче төс алып китәр иде, бәлки... Хәзер үкенеп утыруда ни файда, Муса дөрес әйтә: кызларның чак кына керфек сирпеп алуында да мең битлек китапка сыеп бетмәслек сер ята, аңлый гына белергә кирәк, ди ул. Кирәктер дә, менә Әхмәтсафа әлегә сыната шул, Заһидәнең күңеленә һичничек юл таба алмый...

Сәйдәш уйнаган музыка җанны актара. Бер мәлдә дәртле, кояшлы сыман. Икенче мәлдә күңелне шөбһә, сагыш аһәңнәре күмеп китә. Шушы сагышлы-дәртле моң астында аңлатып булмаслык югалту ачылары бар сыман. Ә бармаклар йөгерә дә йөгерә. Андый нәфис, озын бармакларны беренче күрүе Әхмәтсафаның. Юк, кеше бармаклары болай ук хәрәкәтчән, тыңлаучан булмас, гайре табигый зат иядер аларга...

Күңел һаман саен музыка әсирлегендә бәргәләнә. Хәзер инде Сакмар өстендәге дулкыннарның иртәнге назлы тибрәнүләрен яр буендагы камышларның чәбәләнеп өзгәләнүләре, талларның суга ятып бәргәләнүләре, акчарлакларның илереп елаулары алыштырды кебек. Дулкыннар агарып өскә күтәреләләр, бер генә тынга суга кунарга батырчылык иткән акчарлакларны әллә кайларга, офык аръягына чөеп җибәрәләр кебек. Әйтерсең лә акчарлакларда кеше язмышы төсмерләнә. Әйе, Сәйдәшнең уйнавын яхшы төшенә Әхмәтсафа. Сәйдәш кеше күңеленең эзләнүләрен, үз-үзен табарга омтылып өзгәләнүләрен, шушы юлда кеше язмышына очраган бихисап яктылыклар, дулкын-өермәләр хакында сөйли иде. Омтылышлар, юлда очраган киртәләр, табу-югалтулар, җиңүләр, кире чигенүләр, мәхәббәт һәм нәфрәт, яшәүнең мәңгелеге, гомернең чикләнгәнлеге... Музыка аша шулкадәрле катлаулы нәрсәләр хакында сөйләргә, башкалар белән бәхәскә керергә, килешергә йә килешмәскә, үзеңнең карашларыңны расларга мөмкин икәнлеген егет моңарчы белми иде. Әлеге кичәгә алып килүе өчен Мусага мең рәхмәт әйтсәң дә, аз булыр кебек. Инде көй сагышка чорналып сүндем, беттем, киселдем дигәндә, тагын кояш чыга, тагын көн яктыра, тагын яшисе килү теләге көчәя. Тормышка мәхәббәт тә бар бу көйдә, бер мәлдә күңел кубарылып куя — шом, дөньяга ләгънәт тә ачык чагылган кебек. Сәйдәшнең тыңлаучыларның күңелләре бар тынычлыгын җуеп, урыннарыннан кубарылуында бер эше дә юк сыман, уйнавы уйнау, бармак араларыннан агыла да агыла моң. Әйе, аксыл пианиноның кайсыдыр кыллары чиртелеп хасил булган көй түгел бу, нәкъ менә Сәйдәшнең җанында яралып, аның бармаклары аша тышка саркылган моң иде.

Башка чыгышларны да Әхмәтсафа шушы моң тәэсиреннән аерыла алмый карап утырды. Әнә Муса үзенең шигырен укый. Моңарчы йөрәгенә якын кабул итеп килгән «Авыру комсомолец» шигыре дә нигәдер ул кадәр үк тәэсир итмәде. Бу шигырьне Муса музыка мәктәбендә белем алучы Мәгыйзә исемле кызның пианинода ул чорда яшьләр арасында популяр булган «Титаникның һәлакәте» вальсын уйнаганда укырга ярата иде. Бүгенге кичәгә Мәгыйзә килгән, һәм моны, әлбәттә, Муса алдан ук белеп торган яки алдан ук сөйләшеп куйганнар, Муса эшне пешереп бетерүне ярата, югыйсә шулкадәр ашкынып килмәс тә иде. Музыкасыз гына «Авыру комсомолец»ны укуны ул башына да сыйдыра алмый... Мусаның укуы залга киеренкелек өстәде, көрәш рухын яңартты.

Әхмәтсафа күнегүләр ясый башлагач, көтмәгәндә Сәйдәш пианино янына барып утырды да башта уйнаган көен

кабат уйнап җибәрде. Егет үзен күкнең җиденче катында итеп хис итте. Бу юлы көйдәге күләгәләр каядыр таралган, ул яктыра төшкән, дәртле һәм ашкынулы төсләр өстенлек итә иде. Әхмәтсафа, чыгышын тәмамлап, тамашачыларга баш игәндә генә исенә килде. Моңарчы татымаган гүзәл мизгелләр кичергән иде ул чыгышы вакытында; гәүдәсенең очышларын сизмәде, ә менә хәрәкәтләренең төгәл, җыйнак булуын тоеп, белеп торды.

Кичә тәмамланып, артистлар һәм шагыйрьләр бер-берсенең чыгышын хуплап-мактап торганда, алар янына борчулы кыяфәт белән Шәриф Камал килеп басты:

— Станцадан хәбәр китерделәр, балалар йортына дип күмер кайтарганнар. Шушы төндә үк бушатып бетерергә кушалар. Көндез булса бер хәл, эшчеләр табарга булыр иде дә... Төнгә каршы кемне табасың? Халык таралып бетте өенә. — Ул, күңелсезләнүен яшерергә тырышып, тын калды.

Шул чагында Муса үзенең булганлыгын янә бер мәртәбә раслады:

— Мин хәзер хәрби-сәяси курсларга йөгерәм, — диде ул. Шул арада шинелен киеп тә өлгерде. — Син «Орлес»ка үзең генә барасың инде, дустым. Күмерне кулдан ычкындырып булмый, курсантларны күтәрергә кирәк, — диде, үтә эшлекле тавыш белән. Бу минутта, чыннан да, ул барысына караганда да бер башка өстен тоелды. — Шәриф абый, станцага барып, кәгазь эшләрен карый тор, без бер сәгатьтән килеп җитәрбез, — дип, җавап көтеп тормастан чыгып йөгерде.

— Шәп егет! — дип калды аның артыннан Шәриф Камал. — Нинди эшкә алынса, шул кылә кулыннан. Шәп!.. Ничек барысына өлгерә, исем китә. Үзе арый да торгандыр, бер дә тик тормый бит.

— Кайтып караватка ауган уңайга йоклап та китә, — диде Ченәкәй бүлмәдәше хакында. Ул аны үз малае кебек ярата иде, шуны сиздергәндәй өстәп тә куйды. — Ял ит бераз, бу дөньяның тишек-тошыгы бетмәс аның, һәркайсына бөке булып бетә алмассың, дип тә карыйм. Кая ул, әллә аңа әйтәләр, әллә стенага, колагына да элми...

## X

Яз кояшы, печән чемчекләгән тай шикелле, кар япмасын ялмый. Күзгә сыман ялтырап яткан юка кар элпәсе тыгыз, дымык җил басымына түзә алмый челтер-челтер уала; чана эзләренә кар суы тибеп чыккан. Кыштан тәмам күшеккән җаннарга яз сулышы бөркелде. Болай барса, тиздән Сакмар бозы күтәрелә башлар дип, Каргалыдан килеп укучы яшьләр: Әхмәтсафа, Саттар, Рәхим, Надир һәм, әлбәттә, алардан бер адым да калмый торган Кәрим килеп кушылды, авылга

кайтып килергә булдылар. Егетләрнең шау-гөр килеп җыенуларын шәйләп алган Муса, йөзен нәүмизләндереп, бер Әхмәтсафага, бер Саттарга карап алды. Бик тә әһәмиятле эш майтарырга тиешле булып та, иптәшләренең аны искәрмичә китеп баруларын өнәмичә, аларны ачыктан-ачык шелтәләгәндәй, гадәттәгечә, иреннәрен бүлтәйтеп, инде егетләргә мәзәк сыман тоела башлаган сүзләрен кабатлады:

— Мине дә алып барыгыз әле Каргалыга!.. Күрәсем килә...

Саттар көлеп җибәрде.

— Иренмәсәң, әйдә, җыен, якташ. Каргалы юллары такыр, унбиш китәр, биш кайтыр, диләр бездә. Кимеп түгел, артып кайтыйк әле...

— Каргалыда ни калган? — диде Кәрим төксе генә. Әмма аның сүзләренә игътибар итүче булмады, шаярып-көлешеп, Мусаны юлга әзерли башладылар.

Үзләре белән Мусаның Каргалыга кайтуы яшьләр өчен бер күңелле вакыйгага әйләнде. Чөнки Муса булган җирдә сөйләшергә сүз табыла, сүзгә мавыгып, кайтып җитүеңне дә сизми каласың. Шунысы да бар, Муса кайта икән, димәк, авыл яшьләре белән нинди дә булса кичә оешты дигән сүз. Көзгә кергәч, студент халкы калага, укуга китеп беткәч тынып торган авылга җан иңә. Яңадан да сагынып сөйләрлек, алга табан үзләренә үрнәк булырлык кичәләрне тансыклаган инде авыл яшьләре.

...Язгы кояш яңакларны иркәли, муенга сырпалана-сырпалана куенга үрмәли. Рәхәт дуслар белән бергә авылга кайтулар! Сүз башта кызлар тирәсендә куерыбрак китмәкче иде. Димәк, әллә никадәр серләр, хикмәтләр сөйләнеп ташланачак сәфәр барышында. Муса, күз кырые белән генә Кәримгә карап алды да, һәркем ачык ишетерлек итеп:

— Бүрәнә башы тишек, егетләр,— диде. Әле генә шау-гөр килеп барган юлчылар, Мусаның тел төбен аңлап, сүздән калдылар. Үзләре дә беләләр, Кәримнең гадәте шул: ул башкаларның сөйләшкәнен мыштым гына тыңлап тора да, җай чыгу белән, ишеткәннәрен түкми-чәчми иkенче берәүгә җиткерә. Аның бу гадәтен Муса әле күптән түгел үз җилкәсендә татып та карады.

...Беркөнне тулай торак бүлмәсенә яныл-пешеп килеп керде ул. Йөзләре алсуланган, маңгаена тирләр бәреп чыккан. Бүлмәгә кергән уңайга, беркемгә бер кәлимә сүз катмастан, почмактагы зур савыттан каралып-корымланып беткән калай кружка белән су чумырып алды да каударланып иреннәренә китерде. Ул, дәресләр тәмамлану белән, «Орлес»ка киткән иде, күрәсең, эше саллы булган: әле бит анда халык алдында чыгыш ясап, дөнья хәлләрен сөйләп кенә калмый-

сың, авыр участокта эшләүчеләргә ярдәм итәсең — шулай булганда гына эшче халкы синең сүзеңә колак сала. Соңыннан, эш беткәч, уйнарга да ярый дигән кебек, әбәт вакытында бергәләп ашханәгә барып, тамак ялгап алу мөмкинлеге дә бар. Мусаның шулай кабынырдай булып килеп керүен Әхмәтсафа шаяртып, үзенчә борды:

— Әллә, Муса дус, Җаек аръягыннан ук чабып килдеңме? Ашыкмасаң да әллә ни булмас иде, Гайшәң музыка түгәрәгендә, тиз генә чыкмас...

Муса, кызлар турында сөйләшергә һәвәс булса да, бу юлы битараф кына кулын селтәп куйды:

— Гайшә кайгысы юк әле монда...— Бу сүзләрне һич тә Гайшәгә карата якты хисләренең булмавын гына түгел, ә шушы мәлдә күңелендә тулышып-ташып шигъри утлар уйнавыннан хискә бирелеп әйткән иде.— «Орлес»ка барып, эшчеләр белән сөйләшеп кайттым.— Муса шулай купайтыбрак җибәрергә ярата.— «Орлес» миндә яңа фикерләр уятты. Эшчеләрне тыңлагач, киләчәккә ышаныч, өмет кабынды җанда. Завод эшчесе кулы аша үткән агач-такталардан илнең яңа нигезе төзеләчәк бит, егетләр! Их, егетләр! Болар бит кабатланмас вакыйгалар! Мин бу хакта зур әсәр язачакмын. Әлегә хыял, шулай да кайбер юллары инде күңелдә йөри:

Менә —
Таң аллана...
Гудок тавышы...
Эшче торды, өйдән кузгалды;
Гудок — чәен эчте;
Гудок — эшче
Завод эченә кереп югалды;
Таңгы гудок — эшкә;
Көндез — ашка;
Тагын эшкә;
Эшче гудок белән;
Эшче аңа
Йөрәк тибеше белән ышанган.

Муса әле генә укыган шигырь тәэсиреннән, хисләреннән айнырга өлгермәде, Фатыйх Сәгыйтов, кашларын җыерып, шигырь юлларын тәнкыйть утына да алды:

— Кая монда яңа тормыш, яңа үрләр чаткысы?.. Чәй эчү, ашау... Бәйләнгәнсең шул гудокка. Нәрсәсе бар инде аның? Гудок — чудак... Хи-хи...

Муса аптырабрак калган иде, ярдәм сораган шикелле, иптәшләренә текәлде.

Әхмәтсафа Фатыйхка каршы төште:

— Минемчә, гудок монда урынлы кулланылган. Ул күп нәрсә хакында сөйли. Гудок — заводның эш ритмы, гудок —

үткәннәр хакында сөйләүче хәтер дә, заводның бүгенгесе дә, аны киләчәккә дәртләндерүче көч тә. Гудок — ул эш, шаулап торган тормыш символы. Исегездә булса, кайчан гына завод хәрабә хәлендә иде, хәзер инде тернәкләнеп килә. Муса дөрес әйтә, гудок тавышы — бүгенге көндә илнең йөрәк тибеше ул, өмет, ышаныч уятучы көч…

Муса Әхмәтсафаның җилкәсенә кулын салды һәм арыган тавыш белән:

— Рәхмәт, дустым. Мин бу юлларны нәкъ синеңчә уйлап яздым. Завод-фабрикалар хәрәкәткә килсә, тормыш рәтләнәчәк безнең. Мин моңа ышанам,— диде.

Шушы сөйләшүнең Кәрим барысын да «өзеп» ташлаган да, Мусаның Гайшәгә карата уйнапмы, уйлап бетермичәме әйткән сүзләрен аерып алып, кызның үзенә җиткергән:

— Муса «миндә Гайшә кайгысы юк» дип әйтте. Юкка өметләнмә, ул хәзер борынын күтәрде. Синең кебек авыл кызлары ике ятып, бер төшенә дә керми, завод кызларына күз ата башлаган ул. Телендә «Орлес» та «Орлес». Әйтерсең дөньяда шуннан башка нәрсә юк…

Бу хәлләрдән соң Мусага Гайшә белән аңлашулары шактый авыр булды. Төзәтеп булмас кебек күренә башлаган иде аралар, Әхмәтсафа ярдәмгә килде, Мусаның әйткән сүзләре һич кенә дә кызны кимсетү яки ике арадагы мөнәсәбәтләрне өзү нияте белән әйтелмәгәнен үзенчә оста итеп исбат итте. Ахырда, Гайшә йомшап, Әхмәтсафаны шелтәләп тә алды:

— Кеше арасын көйләп йөргән буласың тагын… Һаман-һаман да болай йөрсәң, кара аны, егет, Заһидәдән колак кагасың!

— ЗаһидәТакташка гашыйк шул. Башка кеше күзенә күренми…— дигән булды Әхмәтсафа. Тыштан сиздермәскә тырышса да, йөрәген нәрсәдер яндырып үтте. Коридор идәненең сары буявы әле күгелҗем, әле шәмәхә төскә кереп уйнап алды. Шулай да сүзен әйтеп бетерергә көч тапты.— Кызлар күңелен белеп бетереп булмый инде… Кайсы китапны алып карасаң да, шушы мәңгелек чишелмәс мәхәббәт төенենә тап буласың. Бездән генә калган нәрсә түгел.

…Каргалыга кайтучылар, юлга чыккандагы уенчаклыктан чигеп, җитдиләнә төштеләр. Авылга кайткач, яшьләр кичәсе үткәрү хакында сөйләшә-сөйләшә атлый бирәләр, Әхмәтсафа гына уйларыннан арына алмый. Үзе юлдашлары белән кичә хакында сөйләшә, күңелендә исә — Заһидә. Баш очындагы кояш яктылыкны нәкъ менә Заһидәнең нурлы күз карашларыннан алган кебек, дым йөгереп коңгырт төстә таралып алга сузылган чана эзе дә Заһидәнең күпереп торган чәч толымнары сыман. Их, кызларны аңламассың. Аның өчен ут йотып, йөрәгенең иң кадерле хисләрен аңа гына бүләк

итәргә әзер Әхмәтсафа белән көн саен очраша, елмаеп-көлеп дусларча сөйләшә дә хәтта, ә менә үзенең күңеле бикле, үткәрми егетне эчкә, юл ябык аңа. Гайшә көлгән була да, Әхмәтсафадан гына торса... Каргалыга шундый уйлар эчендә кайтып керде ул.

Кич җитте. Берәүләр — ызба-читальня, икенчеләр — «кызыл почмак» дип атап йөрткән бинада яшьләр кичәсе үткәрделәр.

Иң элек авыл советы рәисе Зариф абзый җыелган халыкны агымдагы эшләре белән таныштырды, аннан Әхмәтсафа үзенә хас осталык белән илдәге хәлләр турында сөйләде. Халыкның сораулары күп иде.

— Син, энем, бик грамотный инде, әйт әле, иген игеп көн күрүдән башканы белмәгән Рәсәйдә ни өчен мондый афәт — ачлык килеп чыкты?.. Мондый гына корылык элек тә була иде, бу кадәр үк кырылмый иде халык ачлыктан. Аңлап бетереп булмый, аңыштыр әле...

— Әмеркә күпме ашлык бирде микән сәвиткә. Биргәнме, юкмы, әллә халыкның кырылып бетүен көтәме?

— Алманнар ни уйлый микән? Дөрес булса, эрвәлүтсияне алар ясаткан, диләр Лилинга? Вагоны белән акча биргән, диләр... Булгандыр, шулай булмаса, бүтән халыкның башы җитәрдәй эш түгел бу, иеме, энем?.. Көлке түгел, сәмәгүн эчеп, тозлы кыяр ашап пич башында яткан кавемдә эрвәлүтсия кайгысы ди... Һем...

— Әле сугыш бетәме җылы якларда? Бохара якларында халык бик усал, көнем өчен түгел, денем өчен дип яши. Бездә генә ул теләсә нинди малакасус динебезне мыскыл итеп таптап йөри. Анда барып эләксәң...

Әхмәтсафага мондый сораулар таныш иде. «Орлес»та да, ТИНО шефлыкка алган Чебенле авылында да күп бирделәр әлеге сорауларны. Ашыкмый гына, фикерен үзенчә дәлилләп, мисаллар китереп, тиешле урыннарда саннар белән дә «уйнап» алып, төпле җавап кайтарды. Сөйләгәннәренә ышаналармы, юкмы — анысы икенче мәсьәлә, мәгәр яратып тыңлыйлар.

Арадан бер абзый:

— Мостафаның бу малае тел тегермәне тартырга оста икән, каян өйрәнгән, гүпчим сала хәчтерүше димәссең, — дип, башкаларны көлдереп тә алды.

Икенчесе җавап кайтарган булды:

— Дәүләтъяр нәселеннән бит. Каешныкылар.

Әхмәтсафа, сорауларга тәфсилле җавап бирергә тырышып, вакытны шактый исраф итте бугай, пәрдә артында Мусаның ике-өч мәртәбә йөткергәләп алуын ишетте. Ызба-читальняның бер өлешен, өйдән алып килгән чаршаулар белән

бүлеп, «сәхнә» ясаганнар иде, пәрдә читен кайтара төшеп, кемдер ачулы ысылдап алды:

— Җитте, Әхмәтсафа, тукта... Вакыт... Таң әтәчләре кычкыра тиздән!..

Егет авылдашлары алдында югалып калмавына сөенеп бетә алмады. Аның авыл халкына бераз хәтере дә калып йөргән чаклары иде. Теге чакта, гает көннәрендә яшьләр кичәсе үткәреп йөргәне өчен мәчет картларыннан әр-җәбер сүзләре ишетеп, җаны аз бәргәләнмәде. Әткәсенең вафатын да шушы вакыйгага китереп бәйләгәннәр иде, шул истән китми йөрәкне өшетә һаман, әрнүле хатирәләр күңел түрендә әле дә авыр таш сыман бөялеп торалар иде, бераз җиңел булып китте. Аерым кешеләргә рәнҗеп булса да, тулаем авыл халкына үпкә-сапка саклап йөрү егетлек түгел икәнлегенә төшенде. Әнә ничек үз итеп, яратып, хәтта сорауларга җавап биргәндә аның өчен борчылып, ярдәм итәргә тырышып утыралар. Үзен бик тә белдеклегә санап, теңкәсенә тия башлаган Чөлди Хәйбушен: «Җитте, Чөлди, йөдәтмә адәм баласын, Алманнан ничә вагун акча кайтканын каян белсен ул? Лилин аңа килеп хисап ясаганмы кем акчасына әрвәлүтсия ясаганын?!» — дип шелтәләп туктаттылар. Ул, бәхәс куертып тормастан, тыңлаучыларга рәхмәт әйтте дә пәрдә артына ашыкты. Кичәдә аның да катнашасы, авылдашларына «артист» булып та күренәсе бар иде.

Пәрдәне бер якка тартып куйдылар. Кичәнең икенче өлеше башланды.

Беренче булып сәхнәгә Муса килеп чыкты. «Бу кечкенә буйлы егет кисәге ни кырыр микән?» дигәндәй, тамашачыларның кызыксынулы карашлары аңа төбәлде. Бу карашларны Муса үзе дә сизде, ахры, сәхнә уртасында бер генә тын тукталып торды, аннан, ниндидер бер тәвәккәллек белән, тагын бер-ике адым атлап, сәхнәнең алдына, идәнгә тәгәрәшкән бала-чага янына ук килеп басты һәм үз хисләреннән айнымаган кыяфәттә, әллә кайдан, ерак үткәннәрдән дәшкәндәй әкрен генә «Авыру комсомолец» шигырен укый башлады. Тамашачылар аның «р» авазын әйтеп бетерә алмавына сәерсенеп утырсалар да, шагыйрьнең сөйләү куәсенә тиз ияләштеләр. Тора-бара Мусаның тавышы ныгыды, сәхнәләрдә шигырь сөйләп, спектакль уйнап егет шактый остарган иде, тамашачылар аның һәр сүзен «йотып» кына барганына төшенгәч, йөзе алсуланып чыкты, ул инде сәхнә иркендә, үз стихиясендә, чын күңелдән, җаны-тәне белән бирелеп шигырь укый, уку дию генә чынлыкка туры килеп тә бетми торгандыр, ул кечкенә спектакль уйный, тамаша оештыра иде. Ызба-читальняда кем бар, хәтта сәхнә артындагы иптәшләре — бу шигырьне ничә мәртәбә ишеткән сабак-

ташлары да сулыш алырга базмый Мусаны тыңлый иделәр.

Әхмәтсафа, Муса шигырь укыганда, Бибкәй сеңлесе белән алда уйналачак спектакльнең сүзләрен кабатлап алмакчы иде дә, кая ул, уникенче яше белән бара торган түгәрәк йөзле, сөйкемле кыз пәрдә артына яшеренә төшеп, мөкиббән китеп, Мусадан күзләрен ала алмый тора иде. Әхмәтсафа шөбһәгә төште. Муса чыгышы тәмамланугa, пәрдәне беразга гына ябалар да, Муса үзе үк язган «Варенье» дигән кечкенә тамаша күрсәтеп алырга әзерләнгән иделәр. Тамашада өч бала катнаша — ике малай һәм бер кыз. Әле авылга җыенганда ук, кемнәр нинди рольләр уйныйсы билгеле иде. Әхмәтсафа — йорт хуҗасының малае, Саттар — аның дусты, ә менә Әхмәтсафаның, ягъни хуҗа малаеның сеңлесе ролен Пәрваз уйнарга тиеш иде. Алар һәркайсы бу тамашаны дистәләрчә күреп, үзләре дә уйнап, ятлап бетергәннәр иде, тик Пәрваз Каргалыга кайтмады, аны, ялынып-ялварып, ахырәте Заһидә үз авылларына утырмага алып кайтып киткән иде. Монысына да хафаланмадылар, «сеңелкәш» ролен чандыр, кечкенә буйлы Муса яки Надир да бик әйбәт башкарып чыккан булыр иде, тик, Тайфә карчыкның өенә кайтып кергәч, Муса башта нәкъ менә Әхмәтсафаларга тукталырга булды, югыйсә Саттар, Надир, алардан өлкәнрәк сыйныфта укучы Кадыйр — Муса белән күптәнге дуслар, аны үзләренә чакырсалар да, ул, елмая төшеп, рәхмәт әйтеп, чакыруларны кире кайтара торды. Белә иде бит югыйсә — Әхмәтсафаларда тамак ягы да кысынкырак, энесе һәм сеңлесеннән башка кайтуын түземсезлек белән көтеп торучы да юк. Ятим кешенең хәле билгеле инде. Шулай да Муса аларда тукталырга булды. Әхмәтсафа, бердән, башкаларга карата үтә сизгер һәм ихтирамлы булса, икенчедән, аның белән эч серләрен бүлешү рәхәт. Дусты аны ярты сүздән аңлый. Мусаның иң сөймәгәне — фикерен тыңлап бетермәстән аны бүлдерү, белдекләнеп, әңгәмәнең кызуын сүрелдерерлек сүз кыстырып кую. Тисә — тиенгә, тимәсә — ботакка шәкелендәге сөйләшүне Муса җен урынына күрә. Әхмәтсафага ул җәһәттән тел-теш тидерерлек түгел, әңгәмәдәшен сабыр гына тыңлап бетерә, аннан соң, өлкәннәрчә төпле итеп, үз сүзен әйтеп куя. Моңа Муса гаҗәпләнеп тә карый иде — әле унижидесе дә тулмаган егет, ә фикер йөртүе — нужа кичеп, дөнья куган авыл агаеныкы шикелле. «Олпатлык җитми безнең милләткә» дигән сүзләрне ишеткәне бар иде элекке елларда. Әхмәтсафа аңа үз ишләре арасында олпатлык өлгесе сыман тоела иде. Моның шулай икәнен ятим калып, энекәше белән сеңлесенә бердәнбер терәк булуыннан; аларның һәркайсын үзе укыган чорда ачлыктан, ялангачлыктан җәфа чик-

мәслек итеп авылның хәллерәк кешеләренә урнаштырып, вакыты булган саен Каргалыга ашыгуыннан; үзенә тиешле студент паегыннан аларга өлеш калдырып, ара-тирә Оренбурда яшәүче Гомәр абзыйсы җибәреп торган күчтәнәчләрне дә, күз карасыдай саклап, авылга алып кайтуыннан; азга гына булса да туганнарының күңелләрен күреп, бер генә кичкә булса да Тайфә карчык йортына аларны үз канаты астына җыеп, хәл-әхвәлләрен белешеп, сөйләшеп-гөрләшеп алырга җай табарга тырышуыннан да күрергә буладыр. Әйе, аны авылда дүрт күз белән көтеп торалар иде. Әхмәтсафа моны белеп тора, шуңа күрә вакыт табып кайтып килә алса, атна буе туганнары белән очрашу тәэсирендә йөри, андый чакта ул аеруча киң күңеллегә, сүзчәнгә әйләнә, кәефе, кем әйтмешли, җырлап тора иде.

Менә бүген дә Тайфә карчык өенә кайтып керүгә, Әхмәтсафа карчыкка ике-өч шакмак шикәр, кәгазьгә төреп, үтә саклык белән хәстәрләп алып кайтып җиткергән такта чәй кисәген биреп, шуның өчен карчыктан бетмәс-төкәнмәс рәхмәт сүзләре, догалар һәм теләкләр гөнҗәләсе алырга өлгермәде, атылып Әхмәтхан килеп керде. Малай, инде аны авыз тутырып үсмер егет дип атасаң да ярый, ныгып килә, төпле, ышанычлы егет булачагы сөйләшүеннән, абыйсына ихтирамлы карашыннан сизелә иде. Ул арада Тайфә карчык, чәй өлгертеп, аларны өстәл янына кыстый башлады һәм шул чагында... кечкенә өйнең ишеге ачылып китте дә, өйгә якты нурлар чәчеп, бер кызчык килеп керде һәм Әхмәтсафаны кочып алды. Үзе назлы тавыш белән сөйләнә:

— Абый җаным, сагынып беттем! Нишләп кайтышлый безгә кагылып, мине алып китмәдең?

Муса, бер мәлгә сөйкемле баланы гүзәл пәри кызына тиңләпме, телдән калды. Өй әйтерсең ниндидер ым ихтыярына буйсынып, зураеп, иркенәеп китте, кызның бераз иркә, ягымлы тавышыннан түшәмнәр биегәеп, каядыр чиксезлеккә омтылды кебек. Тирә-якта нурлар балкышы, өй эче, мизгел эчендә яктырып, икенче төс алды; барысының да карашлары үзгә хәзер — ягымлы, җылы иде. Кызчыкның килеп кергән уңайга һәркайсын үзенә каратып, үз ихтыярына буйсындыруы чыннан да гаҗәп иде. Әлеге баланың Әхмәтсафаның теленнән дә төшермәгән сеңлесе Бибкәй икәнлеген Муса төшенеп өлгергән иде. Бибиҗамал исемле кечкәнтәй кызчыкка беренче булып «Бибкәй» дип, комиссар Шамил Усманов, хәзер инде атаклы язучы эндәшкәнен дә белә ул. Аның әсәрләрен Муса үзе дә йотлыгып укый, Шәриф Камал, Афзал Таһиров, Заһид Шәркыйны әйткән дә юк инде. Усмановны еш искә алалар, яңа әдәбиятыбызның нәкъ ул иҗат иткән юнәлештә үсәчәгенә шикләнмиләр иде. Өйгә

шаулап-гөрләп килеп кергән әлеге «пәри кызы»на килсәк, Шамил Усманов «исем куйган» көннән башлап, кызга барысы да Бибкәй дип кенә дәшәләр, ул үзе дә шул исемен генә ярата, Бибиҗамал дип дәшә калсалар, хәзер авызын турсайта.

Бибкәй сайрар коштай тынып тормый, авызыннан тылсымлы сүзләр чәчә-сибә Әхмәтсафа тирәсендә бөтерелә. Абыйсы бу очрашудан чиксез канәгать иде, сеңлесенең сырмасын салдырып, табын янына утыртты һәм, бар дөньясын оныткан шикелле, кунакларны сыйлау хәстәрен күрә башлады.

Бибкәй әле һаман үги әнисе белән Фәтхулла абзый йортында яши икән. Үзләренең балалары булмаганлыктан, Шәмсия түти белән Фәтхулла абзый инде Бибкәйне үз кызларыннан ким күрмиләр, хәтта Бибкәйнең абыйсы кайткан саен аның янына ашыгуына бераз көнләшеп тә карыйлар иде сыман.

Чәй эчеп, тамак ялгап алгач, Әхмәтхан — Әхмәтсафаның малайлыкка ялланып, тамак хисабына эшләүче энекәше, хуҗасы янына ашыкты, хәтта бүген булачак кичәгә дә килүкилмәве хакында тәгаен генә әйтә алмады ул. Хәзер малларга күз-колак булуның иң кирәк чагы. Бияләр колынлый, сыерлар бозаулый, сарыклар бәрәнли торган, ягъни малтуарның үрчем вакыты. Үч иткәндәй, артым төнлә яки таңга табан була. Төннәрен күз йомып алырга да туры килми икән көнлекче малайга. Көн туса — бетмәс-төкәнмәс башка эшләр. Әхмәтсафа энесен: «Түз инде, энекәш, бу авыр чорлар үтәр. Сабыр итик, безнең кешечә яшиселәр алда әле. Менә укып кына бетерим дә...» — дип, үгет-нәсихәтләр биреп озатты.

Мусаның башына кызык фикер килде — әгәр Бибкәйне тамашага катнаштырсаң? Кыз бик чая, зирәк күренә. Сәхнә артыннан әйтеп, ярдәм итеп торучы суфлер барлыгын да искә алсаң... Шунысы да бар бит әле: тамашадагы кыз, Бибкәйдән аермалы буларак, артык «сүзчән» түгел, күбрәк хәрәкәт, йөз уйнату-мимикалар аша аңлата әйтәсе фикерен. Моны Муса, әгәр рольдә уйнарга кызлар табылмыйча, малай кешегә уйнарга туры килсә дип, махсус шулай эшләде, Әхмәтсафа сеңлесен күндерә алса, тамаша бермә-бер отышлы чыгачак иде. Бу фикерен ул Әхмәтсафаның колагына пышылдап кына әйткән иде, егетләрнең «сере» үзенә кагылганын сизеп алган Бибкәй, матур күзләрен зур ачып, әле абыйсына, әле Мусага карап алды. Йөзеннән үпкәләү чалымнары йөгереп үтте. Әхмәтсафа, эшне озакка сузмастан (сеңлесе көйсезләнергә дә күп сорамый), Бибкәйне юмалау эшенә кереште:

— Бибкәй, үскәнем, синең бит тамашалар күргәнең бар, әйеме?

Бибкәй аптырап калды. Бая гына зур булып ачылган күзләр, кысылып бетә язып, керфекләре челт-челт итеп уйнап, ачылып-ябылып куйды.

— Тамаша?.. Теге, апалар биеп, абыйлар җырлаган чакны әйтәсеңме? Госман абыйны солдатка алгандагы төслеме?..

— Әйе,— дип җанланып китте Әхмәтсафа. Шул ул вакытта Госман абыйсы исенә төшеп, күкрәк турысында нәрсәдер сулкылдап куйды. Абыйсы киткәннән бирле хәбәр бирмәде. Ничек вафат булган, бернәрсә дә билгеле түгел иде. Үзен кулга алып, Әхмәтсафа сүзен дәвам итте.— Бүген без тамаша күрсәтәбез халыкка, анда уйнарга бер кыз кирәк, син уйнап чыга алсаң, әнә Муса абыең киләсе кайтуда сиңа бик матур яулык җибәрәм, ди, минем арттан.— Сүзен әйтеп бетермәстән, гаҗәпләнүдән авызы ачылып, ирене салына башлаган Мусага күз кысып алды: «Ни сөйләгәнемне беләм,— янәсе,— эшне бозып куя күрмә!»

Моны аңлап алган Муса инде Әхмәтсафаның үзеннән арттырып җибәрде:

— Чынлап әйтәм, Бибкәй. Иң матурын сайлап алам яулыкның. Әле мин синең турында да тамаша язмакчы булып торам.

— Минем турында... тамаша, — диде Бибкәй. Ул югалып кала язды.— Шулай тик торган кеше турында да тамаша уйнап буламы?..— Абыйлар әллә шаяртып, әллә чынлап сөйлиләр, аңламассың. Бибкәйнең мәзәк рәвештә йөзе чытылып алды.

— Тамаша шул...— диде Муса, ул арада Әхмәтсафаның: «Арттырып җибәрмә!» — дигән кинаяле карашын тотып, аңа: «Хафаланма!» —дигәнне аңлатып, күз кысарга да өлгерде.— Бер бик тә чибәр ятимә кыз булган. Нәкъ синең кебек. Исеме Бибкәй булган. Ятимә булгач, аны кыерсытканнар, шул чагында бик матур бер егет, аның шундый авыр яшәвен белеп алып, аны коткарырга дип, көрәшкә ташланган. Егет әллә нинди авырлыклар үткән, әмма кызны коткарам дигән вәгъдәсендә торган, аны золымыннан аралап алган. Билгеле, синең турында ук булмый тамаша, тик сине күргәч, башыма килде әлеге уй-ният. Димәк, языла калса, тамашаның сәбәпчесе син буласың. Бел, Бибкәй, игелек җирдә ятмый, яхшылык һәрвакыт явызлыкны җиңә. Син бүген тамашага катнашсаң, бик зур игелек эшлисең безгә.

Сүзгә Әхмәтсафа кушылды:

— Каргалыда сәхнәгә күтәрелгән беренче карлыгач буласың. Бусы да саваплы эш, сеңлем, бусы да җиңү. Яңа тормыш менә шундый кечкенә һәм зур җиңүләрдән төзелә инде. Синең уеныңны күреп, сиңа башка кызлар иярер. Кечкенә нәрсә, ә мәгънәсе зур — яшь илебезнең нигез ташларын

салышуга тиң ул. Без, сеңлем, үзебез төзегән илдә бик бәхетле яшәрбез. Моның өчен искедән килгән чарасызлыкка, һәртөрле тыюларга, чикләүләргә бик-йозак салырга кирәк. Яңа тормышка ияреп кермәсеннәр алар...

Муса кашын җыерып куйды. Әхмәтсафа мондый чыгышларны «Орлес» заводы эшчеләре алдында күп ясады ясавын, әмма сеңлесе белән дә нәкъ шундый ук агарту эшләре алып баруы... Белмим, Бибкәйнең зиһене бу сүзләрне сыйдыра алырмы, әллә матур гына башланган сүзне бозып кына бетерерме?

Әмма Бибкәй ул уйлаганга караганда зирәк булып чыкты, ахры. Моңа охшаш сөйләшүләр элек тә аз булмаганмы, һич тә югалып калмыйча, ачык тавыш белән Бибкәй ярып салды:

— Миңа яулык та кирәкми, карлыгач та буласым килми, ә сәхнәгә чыгып, тамашада уйныйсым килә. Мин бәләкәй кыз түгел инде, мәктәптә укыйм! Анда төрле тамашалар күрсәтәбез, әти-әниләр алдында чыгышлар да ясыйбыз.

Бибкәйнең бу сүзләре егетләргә канат куйды. Алар кызга тамашаның эчтәлеген бәйнә-бәйнә сөйләп төшендерделәр. Кем нәрсә әйтергә тиеш, Бибкәйнең сүзләре нинди, ул аны кайчан әйтә, нәрсәләр эшләргә тиешлеге хакында җентекләп аңлатып, тамашаның тәүге репетициясен дә ясап алдылар. Сөендергән шул иде: Бибкәйгә тамашаның эчтәлеге ошады, тик шунысы бар — Муса белән Әхмәтсафа «варенье» дип, шәһәрчәләп күпме кабатласалар да, кызый үҗәтләнә-үҗәтләнә «вәринҗе» ди. Тегеләр ныклап үгетли башлагач: «Шәһәрчә әйтсәм, миңа беркем дә ышанмаячак», — дип, егетләрне тәмам аптыраштa калдырды.

...Тамаша башланды. Әхмәтсафа белән Саттарның очрашып сөйләшүләре, Әхмәтсафаның дустының өендә тәмле нәмәрсә булуы хакында сер чишүен, аннан атылып өйгә кайтулары, пыр тузып, вареньены эзләүләре, анысының биек шүрлектә икәнлеген күреп алгач, анда менә алмый иза чигүләр, инде алып, тәмлекәйдән авыз итәбез дигәндә генә, чыр-чыр килеп сеңелләре — Бибкәйнең килеп керүе, ике малайның, тотылмаска тырышып җан-фәрман кылануларын күреп, тамашачылар эчләре катканчы көлделәр. Моның уен гына икәнен онытып, шау-гөр килеп, сәхнәдәгеләр көч биреп утырдылар. Бу кадәр уңышны Муса үзе дә көтмәгән иде. Уен беткәч, тамашачылар тагын бер мәртәбә уйнауны таләп итә башлагач кына исенә килде ул. Озакламый тагын киләчәкләре хакында антлар эчеп ышандыргач кына, җыелган халык тынычлана төште.

Залдагы халыкның таралырга ашыкмавын күреп, Муса, «Ятим бала» дигән шигырен сөйләп, әле генә шау-гөр килеп

утырган тамашачыларның күзләреннән яшьләр сөртергә мәҗбүр итте.

Карагалыдан Әхмәтсафа, энесе, сеңлесе өчен сөенеп килсә — шөкер, исән-саулар, Муса, тамаша өчен канатланып килде — татар дөньясына билгеле Каргалы авылы халкы алдында иҗади имтихан тоткандай хис итте ул үзен. Тамашачылар аны яраттылар, халыкка кирәкле эш майтаруына инанып кайтты. Аны тагын да зуррак иҗат эшләренә илһамландырды бу сәфәр. «Бибкәй кыз» турындагы пьесаны, һичшиксез, язарга кирәк дип уйлады ул, юлдашларының шаяртып сөйләшеп, көлешеп баруларына игътибар итмәстән. Оренбурда ТИНО шәкерте булып йөрү генә аны инде канәгатьләндерми, Мусаның киләчәк иҗат планнары хакында сүз чыккач, бер әдәби түгәрәк утырышында, Әхмәтсафаның чишелеп китеп, Шәриф ага Камал алдында әйткәне бар:

— Сиңа, Муса, Казанга бару кирәктер. Анда башка тормыш, башка сулыш сыман. Юкка гына Тукай, ярыйсы гына тормышны ташлап, Җаектан Казанга юл тотмагандыр. Белем йортлары да, театрлар да, матбугат та Казанда. Оренбур бөтенләй татар дөньясыннан читләште, күр инде Казах иленең башкаласы итеп куйдылар бит. Туганнарымны кешечә урнаштыра алсам, ике дә уйламый, укуымны дәвам итәргә Казан каласына китәчәкмен!..

Әхмәтсафаның сүзләрен Шәриф Камал тыныч кына тыңлап утыра иде, түзмәде, егет белән килешкәнен белдереп, җөпләп куйды.

— Казан башка... Казан кайната да, чарлый да ул. Такташка да әйттем бу хакта. Ул инде Казанда чыныгу алып карады. Әлегә әзер түгел, әзи, ди. Ташкентка юл тотты. Вакытыңны юкка сарыф итәсең, дидем. Казан кайтарачак аны тагын, тартып кайтарачак.

Муса, Такташ турында сүз чыкса, кабынып китә, аны нигәдер хуплап бетермәвен сиздерергә ашыга иде. Бу юлы да әйтмичә түзмәде:

— Такташ бит ул пролетариаттан ерак йөри. Бар язганы гел фәрештә дә, пәйгамбәр турында. Эшче, крестьян тормышын кем язар дип уйлый микән? Аның язганнары кемгә кирәк?..

Шәриф ага Камал хәйләкәр елмайды.

— Такташ инде хәзер үк зур шагыйрь саналырга хаклы. Әле ул әйтәчәк үз сүзен. Шагыйрь ул мишәр егете, шагыйрь! Ә син әйткән пәйгамбәр, фәрештәләргә килсәк, безгә үз динебезне ныклап белергә, җаен табып әдәби әсәрләрдә чагылдырырга да кирәктер. Рухыбызның меңъеллык мирасын

бер селтәнүдә юкка чыгарырга ярамый. Яңа иманга ышанып, үз иманыңнан язу гафу ителмәслек ялгыштыр. Рухи бушлыктан да куркыныч нәрсә юк...

Мусаның күңеле кытыкланды, Шәриф агасына чынлап рәнҗеде бугай. Түгәрәк утырышы беткәнен көтеп, бүлмәнең аргы почмагында серләшеп утырган Гайшә белән Заһидәгә дә игътибар итмәстән, җәһәт атлап чыгып китте. Моны күреп алган Гайшәнең йөзенә кызыл тимгелләр бәреп чыкты. Мусаның болай үпкәләү дәрәҗәсенә җиткәнен берсенең дә күргәне юк иде әле, гомумән, аны үпкәли белми дип йөриләр иде, баксаң, иҗат мәсләгенә кагылышлы мәсьәлә — аның иң авырткан җире икән.

Әхмәтсафа язгы якты көндә, Оренбурга кайтканда, үз уйларына бирелеп атлаучы Мусага карап, шушы сөйләшүне искә төшерде. Җитлегеп киләләр, дөньяга карашлары тамырлана. Сакмар урманнары артында күгелҗемләнгән биек калкулыклар аларга ерактан ук үрелеп карый, нәрсәдер кисәтә, нәрсәгәдер өметләндерә, туктамаска, алга барырга рухландыра кебек. Ә алда ниләр көтә соң? Шушы сорау юлдашларның барысын да борчый, һәркайсы нәүмизләнеп, үз уйлары белән бергә-бер калып шуңа җавап эзли. Язгы көндә оеп утырган Сакмар урманы да, аксыл томанга уралып беткән ераклыклар да дәшмиләр иде... Шунысы билгеле: киләчәкнең ишекләрен беркем дә киереп ачып куймаган, яулыйсы үрләрне үзләренә яуларга, ирешәсе хыялларга үзләренә җитәргә туры киләчәк; иҗтиһад итәргә, чигенмәскә кирәк; алда — кырыс тормыш һәм билгесезлек көтә аларны.

## XI

Нургали Надиев, институт директоры, кызып-кызып дәрес аңлата иде, ишек шакыдылар. Кемнең ашыгыч йомышы төшкәндер, шакучы кабалана иде бугай, директор кадәр директорны болай саксыз рәвештә, ишекне күгәненнән кубарырдай итеп дөбердәтеп, дәресен өзәр дәрәҗәгә җиткереп чакырып чыгарган кеше юк иде әле. Нургали Надиев — гыйлем иясе, карап торуга йомшак, басынкы кеше сыман тоелса да, белем, тәрбия эшләренә килгәндә, үтә дә таләпчән, хәтта бераз кырысрак та кеше иде. Кисәк булган әлеге хәлдән директорның чандыр гәүдәсе сискәнеп китте, бу хәлне шәкертләре сизеп торганын абайлап, кыенсынды да бугай, ул «кем йөри анда, юк-бар эш белән борчып» дигәндәй, үтә ризасызлык белән ишеккә таба атлады.

Әхмәтсафа тәрәзә аша нур яудырган язгы кояштан хозурланып, хәтта дәрестә икәнен оныта язган иде, ишек дөбер-

дәткән уңайга күз алдында бөтерелгән сурәтләр, манзаралар мизгел эчендә таралып, очып беттеләр. Егет үзе дә Нургали Надиевтан ким хафаланмады. Ләззәтле иде уйлары, яшәү ямен тойган кебек булган иде, менә сиңа мә, шапылдап шушы сыйныфыңа кире төшеп утыр инде. Ә егетнең хыял дөньясы шәпләп эшкә керешкән иде бит!.. Имеш, Каргалыда алар гомер кичергән өй түрендәге алма бакчасы янып көлгә әйләнмәгән. Барысы да элеккечә тыныч, хозур, дөньяның үз җае белән агышы. Язгы ямьле көн икән, алмагачлар шау чәчәктә, менә киерелеп зур капка ачылды, пар атка утырып чыгып киткән әтисе белән әнисе шәйләнеп калды. Әнисе Әхмәтсафага таба борылып нидер әйтергә теләгән иде, «ярый инде, үзең беләсең» дигән сыман, яктырып елмайды да саубуллашкан төсле кулын изәп кенә алды. Әтисе — күп сөйләшергә яратмый торган Мостафа агайның кулында каеш дилбегә. Кыяфәте җитди, чак кына дилбегәне бушатсаң, хәзер дулап чабып китәргә торган шәп атларны капкадан чыкканчы көч-хәл белән тыеп барды да капкадан чыгуга дилбегәләрне бушатып та җибәрде. Әхмәтсафа, әүвәл, үзен яннарына алмауларына әткәсе белән әнкәсенә үпкәләгән сымаграк иде, инде алар шундый тизлек белән күздән югалгач, капка төбендә бераз торды да, бу аерылышуга ризалашкан кебек, җәһәт кенә капканы ябып куйды һәм баядан бирле күңелен ымсындырып торган якка — бакча ягына борылды. Бакчага кереп шау чәчәккә күмелеп утырган алмагачларга сокланып карап тора иде, күзенә күренә дип тора: бакча түреннән алмагачларның үзләрен көнләштерерлек ак күлмәктән, ап-ак нәфис өрфия шәл бөркәнгән гаҗәеп сөйкемле кыз килеп чыкты. Үтә килештереп, назландырып кулларын алга сузып торган кыз — Заһидә иде... Егет, бар дөньясын онытып, Заһидәгә табан томырылды, кай арада кыз янына барып җиткәндер, шул шәпкә кызның нәзек биленнән эләктереп алып, кавырсындай җиңел гәүдәсен үзенең күкрәгенә кысты, алсу йөзләреннән, күзләреннән шашып-шашып үбәргә иде исәбе... Нәкъ шушы кадерле, илаһи, кабатланмас хыялый мәлдә ишек шакыды да инде теге бәндә. Их, кем икәнен белергә... Дәрестән соң, чыгып, арт сабагын укытасы иде үзенең. Әйе, мондый пырдымсызны тәпәләп алу һич тә начар гамәлгә чутланмас иде. Әхмәтсафа, нәүмизләнгән җанында уйнаган әрнүле хисләрен тыя төшеп, ишек ягына карап алды. Ишек артында Заһид Шәркыйның аптыраулы, гасабилы йөзе күренеп калды. Бу кеше тиккә йөрмәс, хәер, юк йомышын бар итеп йөргән булса да, аңа кул күтәрелмәс иде... Күрәсең, директорга җиткерәсе хәбәре җитди булгандыр, болай сабырсыз кыланмас иде.

Надиев сыйныф бүлмәсенә шактый вакыттан соң гына керде. Кызып-кызып дәрес биргән җирдән ашыгыч чакырып алынган директорның басынкыланып килеп керүеннән үк шәкертләр ниндидер көтелмәгән хәл булуын аңлап алганнар иде. Директорның какча йөзе тагын да суырыла төшеп, иреннәре күгәреп кысылган. Ул өстәл өстендә чәчелеп яткан әсбапларын җыеп маташкан булды, бик сиздерергә тырышмаса да, борчылуын һич баса алмый, сыйныф журналына үрелгән кулы хәйран калтырый иде.

Дәрес бетәргә күп калмаган иде инде. Нургали Надиев арыган тавыш белән:

— Дәрес бетү белән икенче катка төшәбез. Линейкага... Дәүләтъяров сыйныф синең җаваплылыкта кала,— дип, авыр адымнар белән бүлмәдән чыгып китте.

Дәрес беткәнен хәбәр итеп кыңгырау чылтырады. Үзләрен нинди яңалык көтүе белән үтә дә кызыксынган студентлар, Әхмәтсафаның ни булса да әйтүен көтеп тормастан, ишеккә ташландылар, мондый чакта була торган хәл — институт коридоры корт күчедәй гөжләп алды, барлык сыйныфлар да, сөйләшә-көлешә, әлеге ашыгыч җыйналу хакында фаразлап-гөманлап, икенче катка ашыгалар иде.

Сафларга тезелгән студентлар, бер читтәрәк торган гаять борчулы Нургали Надиевны, башка укытучыларны күреп, тиз арада тынычланып, җитдиләнеп калдылар. Ниндидер күңелсезлек булган, юкса бу кадәрле хафаланмаслар иде укытучылар.

Сафлар алдында әрле-бирле йөренгән Заһид Шәркый, кемнеңдер әйтүен көтеп тормастан, урта бер җиргә басты, нидер әйтергә авыз ачкан иде, директордан узып эш йөртүен чамалап алды, ахры, исенә килеп, вакыт җитте, без әзер дигәнне аңлаткандай, Нургали Надиев ягына карап, башын селкеп алды. Нургали ага сүз куертып тормады, рөхсәт дигәнне аңлатып, ым какты. Заһид Шәркыйның арык куллары йодрыкланган, киеренкелектән бит мускуллары уйнаклап тора. Ул тирән тын алды, йөткереп куйганнан соң, тавышына четерекле хәбәр җиткергәндә генә була торган җитдилек төсмере чыгарып, шомлы буяулар өстәп сүз башлады.

— Иптәшләр, шәкерт-студентлар, укытучылар, тәрбия фронты работниклары! Яшь совет власте җиңү арты җиңү яулап, барлык фронтларда да каршы көчләрне тар-мар итә-итә, буржуазия, капитализм калдыкларын җәһәннәмнең тирән базына чәнчелдерә барып, яңа, шанлы тормышка табан дөлдел атларда җилдереп бара.— Әхмәтсафаның хәтерендә дәрес вакытында туган әкияти манзара яңарды: әткәсе белән әнкәсе нәкъ менә дөлдел атларда каядыр чыгып бара-

лар иде бит... Шәркыйның калтыраулы тавышы егетне тиз кайтарды чынбарлыкка.— Әйе, искелекне туздыру җиңел түгел. Безгә, эшче-крестьянга беркайчан да җиңел булмады, бүгенге көндә дә шулай.— Нотыкчы «Алга табан да җиңел булулары икеле» дип әйтергә теләгән иде бугай, сәяси хата китәчәген искәреп, төртелеп калды.— Без... ни... безнең бу көрәшләрдә түккән каннарыбыз эзсез югалмас, бәхетле киләчәкнең мең аршынлы колачлары офыкта инде бүген үк шәйләнә, ашкынулы адымнарыбызны тизләтеп, шунда табан барабыз. Безне алга барудан бер генә көч тә туктата алмас!.. Юлыбызны беркайчан да ялгыштырмабыз!..

Заһид Шәркый кереш сүзен тәмамлагач, «бу өлеше саллы гына килеп чыкты» дип уйлап, канәгать кенә тамак кырып алды. Инде барысы да түземсезләнеп көткән төп мәсьәләгә күчте:

— Бүген,— диде ул, тавышын әкренәйтә төшеп,— безгә бик күңелсез хәбәр җиткерделәр... Әйтүе авыр, әмма бу хәбәрне ирештерүне миңа йөкләделәр.— Заһид күзләренә сытылып чыккан яшьләрен йодрыгы белән җәһәт кенә сөртеп алды.— Әйе, дошманнар бетмәгән, бар әле дошман. Алар усал, алар явыз. Бүген...— Шәркыйның тавышы үрсәләнеп-чиелдап алды,— губерна комсомол комитетыннан хәбәр китерделәр. Безнең якын дустыбыз, сезнең яраткан укытучыгыз Габдулла Туишны, Чебенле авылы крестьяннарына яңа тормыш төзүдә ярдәм итәргә киткән ару-талу белмәс тынгысыз комсомол иптәшебезне дошманнар үтереп ташлаганнар...

Студентлар сафы, киеренкелектән, аркандай тартылып куйды. Әхмәтсафа Чебенле авылында өч көн элек булып кайткан иде. Ачлык елдан соң бераз тернәкләнеп килгән авылда дошманнар яшеренеп ятуы, хәтта кемнеңдер гомерен өзәргә мөмкин икәнлекне күз алдына да китерә алмады. Каравыл өендә чаршау белән бүленеп алган иске тимер караватта төн куна иде. Көн туса, авыл советында, йомышы төшкән кешеләргә ярдәм итеп, эш кәгазьләре тутырып мәш килде, кич яшьләр, комсомол ячейкасы әгъзалары белән уеннар оештырдылар. Дошман яки явыз ниятле кеше булырга мөмкинме Чебенледә?

Әхмәтсафа, ишетелгән хәбәрдән тетрәнеп, башында чәбәләнгән уйларын тәртипкә китерергә тырышты. Габдулла Туиш губкомның яшьләр белән эшләү бүлегеннән килде укытырга. Көләч йөзле, гражданнар сугышында авыр яралануы билгесе — сул аягына аксап йөри, тарих укыта, шактый белемле, мәгълүматлы мөгаллим. Институтта түгәрәкләр көне җитсә, кичәләр оештырылса, кызлар янына елышып, аларны сөйләндерергә, көлдерергә бик һәвәс иде. Шул сәбәптәндер,

Заһид Шәркый хәбәре иң беренче чиратта кызлар күңелен кузгатты, сафларда кызларның мышык-мышык борын тарткалаганы ешайганнан-ешая иде.

— Еламагыз...— диде Заһид Шәркый, тешләрен кысып.— Дошманнарга үч итеп еламагыз!..— Ул, тавышына тимер салкынлыгы чыгарырга тырышып, Габдулла Туишның кыскача гомер юлын сөйләп алды. Шәкертләрнең нинди яхшы мөгаллимне югалтуы хакында сөйләгәндә, институтның салкын таш стеналарына кадәр сызланды кебек.— Әлегә Габдулла иптәшнең ни рәвешле, кемнәр тарафыннан һәм нәрсә өчен шәһит киткәнлеген белмибез. Әмма аның яшь гомерен дошманнар өзүе факт... Аның якты истәлеген, революциянең меңләгән-миллионлаган корбаннарын яд итеп, «Матәм маршы»н җырларга тәкъдим итәм.— Заһид Шәркыйның яшьле күзләре Әхмәтсафа янәшәсендә торган Зиннәткә төбәлде. Зиннәт — институт күләмендә танылган җырчы санала, революция бәйрәмнәрендә, башка чакта күмәкләп җырларга туры килсә, ачык яңгыравыклы тавыш белән ул җыр башлап җибәрә, аны бүтәннәр күтәреп ала.

Зиннәт үзенә төбәлгән күзләрнең ни әйтергә теләгәнен яхшы аңлады, ярты адым алга атлады, күкрәген киерә төшеп тын алды да җыр башлады. Әмма җыр... гаҗәеп күтәренке рухта иде:

Кузгал, уян, ләгънәт ителгән
Коллар һәм ачлар дөньясы!
Дошманнан үч алсын түгелгән
Үксезләр, коллар күз яше...

Әхмәтсафа, шуны чамалап, Зиннәткә нык кына төртеп алды. Зиннәт шып туктап калды. «Матәм маршы» урынына Сәгыйть Сүнчәләй тәрҗемәсендә өйрәнгән «Бәйнәлмиләл» җырлый башлаган иде ул. Егетнең тигез җирдә абынуын өнәп җиткермәгән Заһид Шәркый көчсез тавышы белән «Матәм маршы»н үзе башлап җибәрергә мәҗбүр булды:

Сез хак корбан булдыгыз шәриф юлда,
Халык хакы өчен тартышканда,
Туп, мылтыкка каршы торып үлдегез,
Газиз халык өчен атышканда...

Линейка тәмамлангач, укытучылар белән бергә институтның комсомол активистлары да, Нургали Надиев бүлмәсенә җыйналып, Габдулла Туишны күмү комиссиясе төзеделәр. Эшләр бүлештеләр. Төп вазифа — күмүне оештыруга җитәкчелек итү профкомның хуҗалык эшләре рәисе Әхмәтсафа Дәүләтъяровка йөкләнде. Оештыру эшләре төгәлләнеп, ат алып Чебенле авылына бару хакында фикер алыш-

канда, ишек киерелеп ачылды, аннан ачудан агарынган, күз бәбәкләре киерелгән... Габдулла Туиш килеп керде. Ул тәмам аптырашта калган, күзләрен челт-мелт йомып торган җәмәгатьчелеккә көтелмәгәнчә кискен тавыш белән ике-өч кәлимә сүз ыргытты:

— Сез, нәмә, анагызны корт чаккырлары, башка эшегез юкмы?.. Исән кешене үтереп, күмеп куярга җыенасыз, панимаешь! Каян чыккан сүз ул? Әнә мине күргәч, Пәрваз һушыннан язып егылды, «үлгән кеше кайтты» дип кенә әйткәнен ишетеп калдым. Шунда әйттеләр кызлар... Панимаешь... Үләсегез бик килсә, үзегез карагыз, панимаешь...

Заһид Шәркый, дустын кочаклап алырга теләп, аңа табан талпынып алды. Габдулланың ачулы йөзеннән шүрләпме, ярты юлда туктап, авыз эченнән мыгырданып куйды:

— Соң бит... Галин хәбәр җибәрде... Чебенле... Дошманнар үтергән, дип... Менә әле линейка җыеп, «Матәм маршы» җырлап... — Дөресен әйткәндә, беренче мәлдә, Шәркый матур башланып, ямьле тәмамланган ихтилалый чараның шулай көтмәгәндә көлкегә әйләнеп калуын өнәп тә бетерми иде... — Үлмәгәнсең икән, — диде ул салкын гына.

— Ни чыкмаса, синнән чыга, Заһид, — диде Габдулла үртәлеп. — Соң, Алла колы, мин бит кичә Сакмарга киттем, губком йомышы белән. Каян барып чыгыйм ди Чебенлегә. Үзең озатып калдың бит, ә? — диде ул, өзгәләнгән кыяфәт белән. — Бу цирктан соң мин шәкертләремнең күзенә ничек карыйм? Мин дәрес биреп маташкан булырмын, алар көлеп утырырлар шунда.

Нургали Надиев, Габдулла Туишның исән-имин әйләнеп кайтуына сөенсә дә, шундый кыен хәлдә калуларына уңайсызланып, Заһидка кырын караш ташлап, аклангандай итте:

— Минем истә иде лә ул Сакмарга китүең. Кинәт бит... Көтелмәгән хәбәрдән исәңгерәп калдым. Шулай була инде: атай үлеп ята, көлеп эчләр ката...

— Кем уйлаган, кем уйлаган, — дип сөйләде Заһид Шәркый һәм кинәт ишеккә ташланды. — Әйдә, Габдулла, губкомга, Галин янына! Барып кайтыйк әле!.. Каян килеп шундый хәбәр тараткан ул, белешик, җавабын институт каршында үзе тотсын, — диде, кызуланып чыгып барышлый. — Әхмәтсафа, син дә бар, шаһит булырсың, тиз генә киенеп чык, көтеп торабыз.

— Әле шәһит, әле шаһит, — дип көлемсерәп сөйләнде Нургали Надиев. — Гаеплене табып, чарасын күрү начар булмас иде. Сабаклар өзелде, укытуның рәте-чираты калмады. Шулай булса да дәресләргә, иптәшләр, — дип, дәртле атлап чыгып китте.

...Институт вәкилләренең килүен түземсезләнеп көтеп торганлыгы әллә каян күренеп тора: Заһид Шәркыйның башы ишектән кереп җитәргә өлгермәде, комсомолның губерна комитетында эшләүче Галин эре тешләрен ыржайтып көлеп җибәрде:

— Нәрсә артын өзгән кигәвендәй кыланасың, Шәркый? — диде ул, башкаларга игътибар итмәстән.— Астыңа су җибәрдемме? Хи-хи...

Галин нечкә тавышын хихылдап көләргә көйләп бетерә алмады, Габдулла, аның изүеннән эләктереп, көчле куллары белән стенага терәп куйды:

— Синең эшеңме, Галин? Мине теге дөньяга озатуны оештырып йөрисең икән. Дус, иптәш дип йөргән мин җүләр.

Галин бу кадәр җенләнеп ябышуын көтмәгән иде Габдулланың. Яшькелт күзләрен шар ачып, ярдәм сорагандай Заһидка, аннан Әхмәтсафага карап алды, көч-хәл белән иреннәрен кыймылдатып:

— Җибәр... Син нәрсә, акылдан шаштыңмы? Буып үтерәсең...— дип кенә әйтә алды.

Габдулла, суына төшеп, кулларын ычкындырды. Галин, карчыгадан ычкынган чебеш сыман, түрдәге өстәл артына, үз урынына атылды. Ул инде үзен кулга алырга өлгергән иде, муенын боргалап алды да чыраен сытып теш арасыннан гына:

— Утырыгыз, аңлашырбыз,— дигән булды. Комачтай кызарган йөзен күрсәтмәскә тырышып, өстәл тартмасына иелде, ниндидер кәгазьләр актаргандай итте, аннан соң гына сүз башлады:

— Иптәш Туишев, беренче ишетүең түгел, мин губкомда яңа йолаларны гамәлгә кертү өчен җавап бирәм. Комиссия рәисе. Син моны яхшы беләсең, Габдулла иптәш! — диде ул, рәсми тонда. Эрелек төсе чыгарып, астан әле Шәркыйга, әле Туишка карап, хәйләкәр кыяфәттә сораган булды.— Бүген нинди көн әле?

Габдулла белән Заһид бер-берсенә карашып алдылар да җавап бир мәгънәсендә Әхмәтсафага төбәлделәр.

— Нинди көн? — дип кабатлап сораган булды Заһид Шәркый.

— Беренче апрель,— диде Әхмәтсафа көттереп кенә.

— Менә-менә...— дип куанды Галин, муен тирәсен ышкып алып.— Бу хакта, әлбәттә, губкомнан хәбәр көтеп ятарга тиеш түгел идегез. Беренче чиратта сез, Заһид иптәш, һәм... син, комсомол әгъзасы булган яшь иптәш. Искелекне бетерәбез, дип лаф орабыз, ике сүзнең берендә яңа йолалар, яңа гадәтләр, дибез, ә үзебез?.. Шушы матур, язгы көндә беренче апрельнең алдау көне икәнлеген берегез дә уйлап та кара-

масын инде! Көлке бу, просто тавык көләрлек хәл. Кая комсомол ялкыны, кая монда яңалыкка омтылу, кая монда, канса да канис, көрәш рухы?.. Юк, юк бит, иптәш Юсупов? — дип, Заһидның инде күптән онытылган үз фамилиясен искә төшерде Галин.— Ә бит бу алдау көнен чын совет бәйрәме итеп үткәрергә булыр иде. Алдау-алданулар, бер-береңне шаяртып алулар. Шуның бик матур үрнәген мин сезгә үзем күрсәтергә мәҗбүр булдым, бигайбә. Күңелле түгелмени — үлгән дип уйлаган иптәшегез, революция солдаты, сез матәм үткәргән минутта исән-имин үз аягы белән кайтып керсен әле! Хи-хи... Тагын нәстә кирәк сезгә, нинди үрнәк көтәсез? Үзегез оештыра белмәгәч... Губкомның ныклы контролендә булыр бу бәйрәм моннан соң.

— Шәп иттең инде, иштең ишәк чумарын...— диде Габдулла, үзе белән шулай усал шаяртуларына әрнүен яшерә алмыйча.— Мине нинди коега төртеп төшерүеңне аңламыйсың бугай, Галин. Шәп казыгансың коены...

— Йә инде бала-чага булма...— Галинның тавышы үпкәле иде.— Кеше казыган коега төшү ул кадәр үк үкенечле түгел, үзең казыганга төшмә син. Революция ясап йөргәнсең, үзең печтек тә аң кермәгән кеше сыман сүлисең... Шаярту бу, просто дусларча шаярту... Адәм көлдереп йөрмәгез, барыгыз, кайтыгыз. Мин әйткәннәр хакында кат-кат уйлашыгыз...

Заһид Шәркый исә, Галин әйтмешли, шундый «простой вопрос»та сәяси сукырлык җибәрүенә, беренче мәртәбә илкүләм үткәрелә торган совет бәйрәменә — алдашу көненә карата шундый да битарафлык, игътибарсызлык күрсәтүенә үкенеп, ишек катында тора иде. Башкалар артыннан ул да дәшми-тынмый кайтырга кузгалды.

— Алдау көне... Алдау көне...— дип сөйләнде Габдулла Туиш тынычлана алмый.— Алдашу нинди бәйрәм булсын ди, ялган җитәрлек бу илдә болай да...

— Җитте, тынычлан,— диде Заһид.— Үзең генә түгел монда, яшь кеше булуын да онытма! Бусы: «Әхмәтсафа алдында телеңә ни килде, шуны сөйләп барма!» — диюе иде, ахры.— Аптырыйм мин,— диде ул, як-ягына сәер каранып.— Нәрсә булган инде — шаяртып алган иптәш. Шуның белән беткән-киткән, син һаман үпкәләп барасың. Аң җитми әле безгә, революцион аң, зирәклек җитми...

## XII

Алдагы елда Әхмәтсафага укырга туры килмәде. Ачлык галәмәте үтеп, халыкка бераз җан иңә башлаган чор иде бу. Хәер, Әхмәтсафаны институтка тартып торучы серле җеп өзел-

де бит — укулар беткәч үк, Заһидә ничә курс тәмам итүе хакында белешмә алды да Такташ артыннан Ташкентка китеп барды. Саубуллашып китте. Соңгы көннәрнең берсендә институтның аулак почмагында Заһидә белән күзгә-күз очраштылар алар. Заһидә үзенең Ташкентка китәргә җыенып йөрүен әйткәч, әллә институтның биек түшәме өстенә җимерелеп төште — Әхмәтсафаның аңы томаланып, шактый вакыт зиһенен җыя алмый торды.

Кыз, Әхмәтсафаның тәмам бетәшкән төстә каршында торуына ачуы килепме, кырыс тавыш белән өстәп куйды:

— Җегет булсаң, җебеп торма! Теләсәң, поездга озатып куярсың. Ә мин Такташны барыбер эзләп табачакмын. Синең белән дуслар булып калырбыз.

Әхмәтсафа, үзен кулга алып, ни өчендер кызны бу хәвефле юлга чыкмаска үгетлисе итте:

— Ашыкма, Заһидә. Укуыңны бетер, Ташкентта, теге... Такташың да качмас. Бәлки, бергә китәрбез ул чакта.

— Илдә чыпчык үлми,— диде Заһидә, Әхмәтсафаның «бергә китәрбез» дигән сүзләрен ишетмәмешкә салышып.— Такташны һич кенә дә күңелемнән куып чыгара алмыйм, аның өчен мине битәрләмә, зинһар. Ул минем җанымны, вөҗүдемне биләп алды. Матур җегет иде. Татар тотып карамый ышанмый дигәндәй, минә минем дә шул матурлыкны тотып карыйсым килә.— Кыз әллә чын сөйли, әллә, гадәтенчә, шаяртуга күчеп алды, егет аңышып бетми тора иде, Заһидә сүзне икенчегә борды.— Хәзер бөтен татар Ташкент ягына сыптыра. Бу якта калып, ачлыктан кырылып бетәсе килми кешенең. Быел җәй ничек булыр? Барысы да Ходай кулында бит, Әхмәтсафа. Без генә йөргән булабыз артны күккә асып...

Кыз китәм дип хыялланган, аны бу уеннан кире кайтарып булмаячагы көн кебек ачык иде. Әнә бит ничек фәлсәфә сатарга тотынды Заһидә. Кычыткан чыпчыгы шикелле сикергәләп йөргән кызчык димәссең.

— Акылны Ходай юкка гына бирмәгән кешегә. Бернәрсә дә юкка бирелмәгән. Акыл булгач, уй дигән нәрсә дә бар. Башка уй килеп кергән икән, инде аның да хуҗасы — Ходай дигән сүз. Ходай язмаган эш булмас, мин тәвәккәлләп юлга кузгалам, дустым.— Заһидәнең керфек очында көмештәй яшь тамчысы елтырап китте.— Барып урнашкач та, кызларга хат язармын, алар хәбәремне җиткерерләр...— Кыз, җавап көтмәстән, йөгерә-атлый беренче катка төшеп китте.

Әхмәтсафа кызны озатырга бармады. Күңелендә үҗәтлекме, үпкә хисеме кузгалды, хәер, анысы артык мөһим түгел иде инде, ни булса да булды — кызның китүен бик авыр кабул итте ул. Заһидә киткән көннән бирле аягы институт-

ка тартмый тек тартмый инде. Күңелне юатырлык бер нәрсә бар — бу җәйдә, ниһаять, үзләре элек яшәгән Сакмар очындагы нигезләренә саманнан өй корып керергә җыена башладылар. Бу эшне бигрәк колчакчыларны җиңеп авылга кайтып егылган Гомәрхан абыйсы ашыктырды. Аның һич кенә дә Тайфә карчык йортында яшисе килми иде. Үзе, сугыштан кайтып керүгә үк, хәллерәк кешеләрдә батрак булып ялланды, соңгы кышта Зариф, башлы егет дип, аны авыл советына секретарь итеп эшкә алды. Сәвит тирәсендә йөри торгач, бераз уңга-сулга карый башлады. Утлар-сулар кичеп кайткан солдат йортсыз-нисез йөрсен инде. Моның белән ничек килешмәк кирәк?.. Янып көлгә әйләнгән нигезләре, йөрәген әрнетеп, шул килеш таралып ята. Язгы чәчүләр беткәч, Әхмәтсафа белән киңәште дә Бәдертдин байда көнлекче малай булып йөргән Әхмәтханны чакыртып алды. Авыл советы сәркатибенә бай абзый карышырга батырчылык итмәде, үзләренең көннәре санаулы гына калып баруын ул чамалый иде инде. Егетләр эшкә җан-фәрман тотындылар. Ихата арасын яхшылап чистартып, янгыннан калган чүп-чарны Сакмарның биек ярыннан аска түктеләр. Абыйлары янына уникенче яшен тутырып килүче сөйкемле кыз Бибкәй дә килеп җитте. Ул һаман да үги әнисеннән аерылмый, Шәмсия белән Фәтхулланың асрамага алган кызлары булып яши иде. Атна дигәндә йортка нигез салынды...

Әхмәтсафа үткән ел яшьләр белән бергәләп оештырган итек тегү мастерскоендагы эшне җанландырып җибәрде. Аңа Саттар да килеп кушылды. Булышчылары да табылды, иң мөһиме, мастерскойны авыл советы рәисе Зариф абзый үз итә, үткәндә-сүткәндә кереп чыга, кулыннан килгәнчә егетләргә булыша иде.

...Җәй урталары җиткәч, «Якын-тирәдә угрылар йөри, совет хакимиятенең дошманнары яңадан баш калкыта икән» дигән хәбәрләр ишетелә башлады. Авыл активистлары, коммунистлар Зариф абзый җитәкчелегендә ЧОН отряды төзеделәр. (ЧОН — часть особого назначения. Җирле партия ячейкалары тарафыннан төбәкләрдә контрреволюциягә каршы көрәшү, тәртип булдыру, дәүләт милкен саклау өчен төзелгән отряд.) Отряд әгъзалары төннәрен авылны төрле угры-караклардан, дошманнардан саклау нияте белән кизү оештыра башладылар.

Гомәрхан да өйгә мылтык күтәреп кайтып керде беркөнне.

Әхмәтсафа мылтыкны күргәч кызып китте, авылны саклаучылар сафында булмавына үкенеп тә куйды хәтта. Нинди кызыклы гаҗәп хәлләр булмас дисең, ә ул комсомол башы белән төннәрен башын чикмән астына яшереп ятсын ди?!

Әлеге уйларын, икенче көнне мастерскойга килгәч, Саттарга да сөйләде.

— Авылның комсомол ячейкасы бар, алар нигәдер кымшанмыйлар бит,— диде Саттар, Әхмәтсафаның кайнарланып сөйләвен бүлдереп.— Өлкәннәр йөри дип... Аларның күпчелеге гражданнар сугышында булган, утны-суны кичеп кайтканнар. Бездә ни корал юк, ни әйткән кеше юк.

— Кем әйтсен безгә?! — дип янә кызып китте Әхмәтсафа.— Ни өчен комсомол булып йөрибез, шундый эшләрдән читтә йөргәч? Мусадан үрнәк алырга кирәк безгә — мылтык күтәреп дошманнарга каршы йөргәндә, үзе дә мылтык буе гына иде.

— Каян алабыз мылтык? — дип сорады Саттар.— Кулга таяк тотып чыгып булмый бит. Аннан барыбер яшьләрне күтәрергә кирәк. Комсомол ячейкасы ни уйлый?.. Шәһәрдә кыш буе таракан симертеп яттылар да, хәзер эшем ияләре булган булып, безнең эшкә кысылып йөриләр диюче табылмас дисеңме?

— Димәсләр! Дөрес аңлату бездән тора. Үзебездән башларга кирәк,— диде Әхмәтсафа, ышанычлы тавыш белән.— Мылтыкка килсәк, Гомәрханның мылтыгы өйдә тора, үзе төнлә авыл советында кунып йөри. Аңа шундый фәрман бирелгән. Инде бер атна буладыр, өйгә көндезләрен генә кайтып китә. Мылтыгы хакында онытты да бугай инде. Аңа нәрсә, сәвиттә корал җитәрлек...

— Бездә ау мылтыгы бар,— дип сүзгә кушылды Рәхим.— Әткәй чормага яшереп куйган иде, ике-өч ел тузан җыеп ята шунда, хәзерауга йөрер чак түгел, алып төшеп чистартсаң...

— Чынлап еласаң, сукыр күздән яшь чыга,— дип куанып сөйләнде Әхмәтсафа.— Ә син таяк дисең. Менә өчебезгә ике мылтык булды. Беребез чыннан да таяк белән йөрер. Корал эшләр, ир мактаныр, сугыша белсәң, таяк та корал.

...Караңгы төн. Сакмар ягыннан Каргалы очына табан тавыш-тынсыз гына шәүләләр шуышкан кебек. Төнге күк йөзен алама болыт кисәкләре камап алган, шул әләмсәләм болыт арасыннан сирәк кенә ай карап ала, ул чагында йөрәктәге шом тарала төшә, шәүләләр пышылдап кына сүз алышалар, үзләренең кай тирәдә йөргәннәрен чамалап алалар, якын-тирәдә хәвеф-хәтәр булмавына ышангач, тагын алга атлыйлар. Болар — Әхмәтсафа, Саттар, Рәхим, ягъни төнге авылны дошманнардан сакларга чыккан яшьләр иде.

Шактый йөреп тә, шикләнерлек нәрсә күренмәгәч, егетләр бөтенләй тынычлана төштеләр, караңгыга да ияләште-

ләр, аннан мылтыклар да яхшы иптәш, ышанычлы терәк, корал бар чагында курку чигенә икән, егетләр, кыюланып, ник чыкканнарын онытa язып гәпләшеп баралар иде, зират тыкрыгыннан каршыларына әзмәвердәй карачкы килеп чыкты. Егетләр, көтелмәгән хәлдән аптырап, телдән калдылар, Рәхимнең кулындагы мылтыгы төшеп китте.

— Кемнәр йөри? Кая бару әле? — диде кырыс тавыш. Аның Зариф абзый тавышы икәнен шәйләп алдылар.

Әхмәтсафа тотлыгып җавап бирде:

— Ком... комсомоллар... без. Кизүдә...

Зариф мыскыл иткәндәй көлеп куйды:

— Сүз әйтмәс борын комы коела башлаган комсомоллар икән әле.— Ул, җәһәт иелеп, Рәхимнең мылтыгын җирдән күтәреп алды.— Комсомоллар түгел сез — хәчтерүшләр! Нишләп кизү хакында авыл советы белми, теркәлми-нитми кем чыгарга кушты сезгә?

Әхмәтсафа батыраеп китте:

— Бөтен активистлар угры-дошманнарга каршы күтәрелде. Шундый чакта без яшьләр йоклап ятарга тиешме? Сөйләштек тә чыктык менә...

— Кемнәр соң сез, балакайлар,— дип, Зариф шырпы сызып җибәрде. Сүрән яктыда егетләрне төсмерләп, көлә төшеп санап алды:

— Әхмәтсафа, Саттар, Рәхим... бәй, студентлар түгелме соң сез? Авыл комсомоллары үз белдекләре белән кизүгә чыккан дип торам тагын. Аларга да задание бирелгән, аларның эше башка. Ә син Каеш — молодец! Шулай да сак йөрегез, егетләр. Бүтән көннәрдә өлкәннәр белән җыйнаулашып чыгарсыз, каршыгызга очраган беренче кешене күрү белән мылтыгызны җиргә ташларлык булгач, чыкмасагыз да сүз юк.

Рәхим, аклангандай сөйләнеп, Зариф кулындагы мылтыкка үрелде:

— Бавы күгәреп беткән, каһәр төшкеренең... Каршыга шәүлә килеп чыккач, җилкәдән тартып кына алыйм дигәнием... Өзелде, шайтан...

Егетләр көлешеп алдылар. Зариф абзый көтмәгәндә ничек пәйда булса, караңгылык эченә кереп, шулай ук юкка да чыкты.

Кизү торучылар, авыл башына чыгып, озын сөзәк калкулык буйлап сузылган юл буенда тукталдылар. Тирә-юньне җентекләп күзәтеп торсалар да, шикләнерлек нәрсә сизелмәде. Төн таңга авышкач, тәннәргә суык үрмәли башлады, керфекләргә мыскаллы йөк асканнармыни, ябылабыз-ябылабыз дип кенә торалар, тизрәк кайтып сәкегә авасы килә. Мас-

терскойга да төштән соң гына җыелырга сүз куешып, кайту ягына борылганнар иде, ерактан йомшак кына ат тоягы тавышы ишетелде. Иң гаҗәбе — шул арада аларның өстенә үк диярлек бер җайдак килеп чыкты, егетләр, үзләре дә сизмәстән, юл читендәге уйсу җиргә чүктеләр. Болай соңга калып килүче мөсафир кем булыр? Зариф абзый белән очрашу чирканчык алдырган иде, бу юлы егетләр, шактый кыю булырга тырышып, җайдак килгән якка текәлделәр.

Җайдак, һичшиксез, алар яныннан ук үтәчәк иде. «Бәлки, кем икәнен чамалап та булыр?» — дип уйлап алды Әхмәтсафа. Әмма ат, алар поскан җиргә йөз-йөз илле адым кала, юлны ташлап, бакча киртәләре буйлап, Сакмарга табан төшеп китте. Сәер, бик сәер иде бу хәл. Егетләр, алдан сүз куешкандай, җайдак артыннан кузгалдылар. Гаҗәп бит кеше дигәнең — әле генә үзләренең шәүләләреннән өркеп, шикләнеп йөргән егетләр чын эшкә керешкәч, бөтенләй курку белмәс кешеләргә әйләнделәр дә куйдылар. Күкрәктә ашкынып типкән йөрәк тә куркып түгел, ә шушы сәер хәлне тизрәк ачыкларга, эшнең төбенә төшәргә ашыктырып җилкенә иде. Ахыр чиктә, уйласаң, егетләр татлы йокыларын калдырып, ни дип михнәт чигеп йөрделәр? Дошман йә угры тотабыз дип, кайнарланып чыктылар бит кизүгә... Менә, бирим дигән колына, чыгарып куяр юлына ди, шикле бер җайдак килеп чыкты. Аның урамга кермичә, ниндидер яшерен нияте бар сыман, авыл читеннән Сакмар ягына төшеп китүе көтелмәгән, әмма бу катлаулы көрәш чорында булырга бик тә мөмкин хәл иде. Кем генә йөрмәс диген мондый болганчык чакта, кемдә нинди ният юктыр дисең? Шуңа күрә егетләрнең берсендә дә икеләнү-курку тойгысы калмады. Сак кына, җайдакның артыннан барып, аның кем икәнен, нинди ният белән килүен ачыкларга, моның өчен иң кимендә аның кем йортына кереп китүен чамалап калырга кирәк иде. Инде юлчы, Сакмарны кичеп, аръякка китмәкче икән, бигайбә, егетләрдә мылтык бар, атып шау-шу кубарачаклар. Авылдагы ЧОН отряды йокы бүсеп ятмый торгандыр, күтәрелеп чыксалар, бу җайдакның эше хәл ителде дигән сүз. Аларда ат та бар, корал да җитәрлек. Сәер юлчы исә әрәмә-урман арасында озак яшеренеп йөри алмас, егетләрнең белүенчә, анда да яшеренгән кизү торучылар бар. Тиз шәйләп алырлар.

Җайдак бер дә ашыкмый төсле тоелды егетләргә. Алар, хәтта артык якынаеп, вакытыннан алда үз-үзләрен ачмас өчен, адымнарын акрынайтырга мәҗбүр булдылар.

Әйе, җайдакның яшь-җилкенчәк кенә булмыйча, чандыр, озын гәүдәле икәнен дә искәреп була иде инде — дөньяга таң

нурлары сирпелеп, күк түре күтәрелә төште. Бу хәл егетләрнең дә эшен кыенлаштырды. Җайдак исә һич кенә дә Сакмар аръягына чыгып китү турында уйламый иде, бакча буен үтеп, аскы урамга борылды, бер ихата яныннан узганда, атын кинәт уңга борды да лапас-каралты артларына кереп юкка да чыкты. Егетләр адымнарын тизләттеләр. Юлчы ташландык йортның җимерек киртә арасыннан түр бакчага чыккан, анда исә берничә хуҗалык-каралты артлары аша үтеп, әллә алдан хәзерләнеп куелган, әллә анысы да җимерелеп беткән булган, аратасыз киртәлек аша аулак тыкрыктан чыгып, каршы як урамга үткән. Озакламый аның үзен дә искәрделәр. Җайдак үзенә генә таныш сукмаклар буйлап бара, аның бу авыл кешесе икәнлегенә шик калмаган иде инде. Ул икенче бер тыкрыктан Сакмар буендагы соңгы урамга чыгып барган җирдән, янә уңга каерып, бакча артына үтте, атыннан сикереп кенә төшеп, лапасның арт капкасын ачып, атын эчкә үткәрде, үзе җиңел хәрәкәтләр белән тыкрык киртәсен рәткә китерде һәм ачык капкадан лапас эченә кереп сеңде. Эчтә хатын-кыз тавышы ишетелеп калды, аңа каршы тыенкы гына ир-ат нидер җавап кайтарды, шуннан башка ник бер тавыш әсәре булсын... Егетләр инде тыкрык ягына ук чыгып торган лапас янына килеп җиттеләр, тыңланган булдылар, әллә җайдакны аты-ние белән җир йотты, шым иткән тавыш-фәлән юк иде...

Әхмәтсафа, Саттарның колагына иелә төшеп:

— Фәтхулла абый бит бу. Алар ихатасы,— дип пышылдады.

— Беләм,— диде Саттар.— Бездән ерак тормыйлар ич инде алар. Тик Фәтхулла абыйның аты юк бит аның. Каян кайтып килеше микән болай?

Рәхим тынын кысып ыслап алды:

— Фәтхи атсыз торыр ди... Аларның нәселе ат карагы бит. Кәсепләре шул. Димәк, Фәтхи янә шул шөгыленә керешкән, сугыштан кайткач.

— Нишлибез? — дип аптырап сорап куйды Әхмәтсафа. Болай гына ихатага барып кереп булмый, аннары бит әле сеңлесе Бибкәй дә шушы йортта. Алар йорт хуҗасының шикле эшен фаш итәргә йөриләр, кызчык бер хәбәрсез йоклап ята торгандыр.

— Тире җыеп, күн эшлибез,— диде Саттар, белдекле кыланып.— Зариф абзыйны табарга кирәк, әллә кайда йөрми торганнардыр әле. Без үзебез ни эшли алабыз? Бар, Рәхим, урамны әйләнеп чык, кизү торучылар очраса, хәбәр салырсың. Без монда — лапас ышыгында көтеп торабыз. Мылтыкны калдыр миңа, сиңа кирәге юк аның.

Бер сәгатьләп вакыт үтте, инде таң ата, тирә-як яктырып,

бөтен нәрсә уч төбендәгедәй күренә иде, арып-талып, өстерәлеп диярлек Рәхим кире алар янына килеп егылды:

— Беркем юк урамнарда, хет бөтен авылыңны талап алып китсеннәр. Хәтта авыл советы ишеге дә бикле. Шакып та карадым, ачучы юк,— диде ул зарланып.

— Яктыра башлауга, таралышып беткәннәрдер. Авыл мужигы бит алар. Тиздән көтү кузгала,— диде Саттар.— Монда таптанып торып булмый, әйт, Әхмәтсафа, нишлибез?

— Без ни өчен чыктык соң? — диде Әхмәтсафа, бәхәскә урын калдырмыйча.— Авылны дошманнардан, угрылардан сакларга дипме? Шикле нәрсә бар икән, белергә кирәк. Хәзер үк ишекләрен шакып уятабыз Фәтхулла абзыйны. Сорыйбыз, каян кайткан, кайда йөргән?..

Рәхим каршы төште:

— Фәтхулла абзый нинди дошман булсын инде... Һем... Кеше бимазалап йөрмәек. Әйдәгез, кайтаек та ятаек. Болай да аяк атлар хәл калмады.

— Кайтасың килсә кайт. Мин эшне өзмичә, ярты юлда калдырмаячакмын,— диде үҗәтләнеп Әхмәтсафа һәм урамга табан атлады. Аңа Саттар белән Рәхим дә иярде.

Капканың эшермәсен шудырып, эчкә үттеләр. Икеләнү, шөбһәләр юкка чыкты. Әхмәтсафа башта саграк, бераздан катырак итеп ишек шакыды. Өй эченә җан иңде, кемдер нык басып өйалдына чыкты, ишекнең келәсен өскә чөйгән уңайга, егетләр һич көтмәгәнчә, хуҗа кеше дәшми-нитми, ишек катына кемнәр килүен дә белешеп тормастан, авыр ишекне шартлатып ачып та җибәрде. Егетләр, төн уртасында нәкъ Зариф абыйны очраткан чактагы кебек үк, үзләренә терәлә язып ак күлмәк-ыштаннан өрәктәй басып торган Фәтхуллага карап, телсез калдылар.

Фәтхулла исә, исе дә китмәгән кыяфәт белән:

— Ни бар, Каеш, нигә кайтып ятмыйсың инде? — дип сорады. Әйтерсең егетләрнең кизү торуын да, артыннан сагалап төшүләрен дә яхшы белә иде ул.

Әхмәтсафага җан керде:

— Кизүдә без...— диде ул, шыр җибәрделәр дип уйламасын дигәндәй сүзләрен ачык һәм кычкырып әйтергә тырышып. Фәтхулладан шүрләргә исәпләре юк икәнлеген белдерергә теләп, шул кимәлдә сүзен дәвам итте.— Менә сезнең ихатага бер атлы кеше кереп китте. Шуңа аптырап, белешергә дип кердек.

— Атлы кеше? — дип кайтарып сораган булды Фәтхулла. Мылтыклар тотып, бик мөһим эш башкарган кыяфәттә торучы егетләргә бертын карап торды да, киң күңеллеләнеп, аларны өйгә үтәргә кыстый башлады.

— Килгәнсез икән, керик инде, сөйләшербез, белешербез дигәндәй...

Әхмәтсафа авыз ачып сүз әйткәнче, Рәхим җавап бирергә өлгерде:

— Кереп-нитеп тормыйбыз, Фәтхулла абый. Ат сезнең ихатага керде. Юлчының кем икәнен әйтегез дә без, авыл советына барып, теркәтеп куябыз. Озаклап сөйләшеп торырга вакыт юк. Инде, озакламый көтү кузгала, ашыгабыз,— диде ул, сабырсызланган кыяфәт белән.

— Уң аякка итек кигәч, сул аякка чабата элеп йөрмиләр бит, энекәшләр, әйдә, килгәнсез икән, ишек төбендә туктап калмагыз. Бездә тәртип шундый,— дип, Фәтхулла Әхмәтсафаның җиң башыннан эләктерде дә өйалды эченә суырып та алды. Аның артыннан, башын түбән иеп, елан авызына ирексез кереп баручы куян баласы шикелле, Саттар кереп китте.

Рәхимнең башы эшләде, ул:

— Минем вакыт юк, кайтышлый кереп хәбәр салырсыз,— дип кырт борылды да капкага йөгерде.

— Һәй, чикерткә,— дип калды аның артыннан Фәтхулла.— Йөрисез шунда, ком иләп...— Рәхимнең болай чыгып сызуына ачуы килде, ахры. Егетләрнең эчләренә җылы йөгерде.

Өйгә үттеләр. Шәмсия аяк өстендә иде инде. Аптыраулы карашын Фәтхуллага төбәп алды. Тегесе мәгънәле генә күз кысты:

— Карчык, егетләр килгән, бар әле, кар базыннан катык алып чык, төн буе кизү торып карыннары ачкандыр, минем дә тамак ялгап аласы килә. Син кергәнче, без гәп куерта торырбыз.

Шәмсия «ә» димәде, «җә» димәде, башындагы яулыгын әйбәтләп бәйләгәндәй итте, чөйдән бишмәтен эләктереп, мич аралыгына кереп китте, кулына ташаяк күтәреп, янә өстәл янына килеп, тәрәзәгә күз салды, шуннан соң гына чыгып китте.

— Түргә, өстәл янына үтегез,— диде Фәтхулла аптырашып торган егетләргә.— Мылтыгыңны әнә почмакка куясыңмы соң? — Бусы Әхмәтсафага төбәп эндәшүе иде.

Әхмәтсафа юк дигәндәй башын селкеп алды да өстәл түренә кереп утырды. Мылтыгын бот арасына кыстырды. Саттар исә кыенсынып кына Әхмәтсафа янындагы бүкәнгә чүмәште. Фәтхулла егетләргә көлемсерәп карап торды да, аларның каршыларына килеп утырды һәм җитди итеп сүз башлады:

— Әй дөньялар...— диде ул, сызланган сыман.— Бар иде заманалар, үтте-китте, юк инде...

Әхмәтсафа каш астыннан Фәтхуллага карап алды.

Фәтхулла озын пычак алып, йөзенә бармак тигезеп, үт-

кенлеген тикшергәндәй итте, аннан җәһәт үрелеп, өстәл уртасында чигүле япма астыннан түгәрәк ипи алды, бисмилласын әйтеп, күкрәгенә терәп ипи кисә башлады. Үзе сөйләнә бирде:

— Бик ерак сәфәрдән кайттым, егетләр, ерак сәфәрдән. Ну уңышлы булды юл. Инде күргәнсез икән, яшереп торыш юк, бер казах баенын нәселле чаптарын урлап кайттым... Төн чыкканчы йөз чакрым гына юл үтелгәндер. Авылга кайтып кергәндә генә аруы сизелде мәхлукның.

— Ат урладың? — дип гаҗәпләнеп сорады Әхмәтсафа.

— Нигә гаҗәпләнәсең, энекәш? Әллә беренче ишетүеңме? Бу кәсеп Каргалы белән бергә яралган бездә. Сәүдәгәрләр нигез салган кала бит бу. Аны болай гына авыл-сала дип йөргән булалар. Тегенди-мондый калаларны орып бирә ул Каргалы. Каргалы да түгел әле ул, Кыр-кала дип аталган әүвәл. Аннан телгә кереп киткән Каргалы булып.

Авыллары Каргалы,<br>Бар да тимер арбалы.<br>Каргалыдан үткән чакта,<br>Күлмәк-ыштан калмады, —

дип зар елап җырлый торган булган элекке мөсафирлар. Угрылар күп булган монда. Ат каракларына тел тигезмәгез, алар икенче чутта. Теләсә кем эше түгел ул ат урлау. Менә шул, энекәшләр, кайда патша — шунда алдашу, кайда сәүдә — шунда урлашу. Һәр халыкның үз кәсебе. Менә урысларны ал — аларда юлбасарлык, башкортларда кыз урлау матур гадәт, йола санала, Каф тавы халкы кеше урлап кәсеп итә. Аларда иң үтемле мал — кеше. Хайван урынына да күрмиләр кешене. Татарда исә мондый кәсептән — ат урлау. Шунсы бар ат хуҗасы да зыянланмаска тиеш, урланган ат та исән-сау килеш башка кулларга тапшырылырга тиеш. Бу — канун. Ат урлаганда кан түгелү булдыксыз бәндәләр гамәле. Кергән табышның да зәкяте тиешенчә түләнергә тиеш. Ятим карт-карчыкка, ятим-җилпегә. Бу яктан, Аллага шөкер, ата-баба йоласына хилафлык китергән юк, инде ничә ел ятимнәргә ярдәм итеп, тамакларын туйдырып, өс-башларын карап торабыз, — дип, Әхмәтсафага карап елмайды. — Шулаймы, Әхмәтсафа энекәш? Ачлык елны пар канатлы гаиләләр дә бала-чагаларын саклап кала алмадылар әнә, рәттән кырылып беттеләр. Каешныкылар, шөкер, барысы да исән, барысы да имин.

Әхмәтсафа бу сүзләрне кызышып тыңлап утырды. Колакларына кадәр кызарды. Йокы дигән нәрсә әллә кая качты, маңгаена тир бәреп чыкты. Саттар да тавыш-тынсыз тыңлап утыруын белә. Фәтхулла исә дәвам итте:

— Йорт башларга исәплисез икән. Дөрес эшлисез, Тайфә карчыкның тавык алачыгына сыеша алмыйсыз инде сез. Бик матур үсеп киләсез. Сеңлегезне дә үз яныгызга алырсыз. Мин быелдан калмам, Хива ягына китәргә исәп. Анда туганнар бар. Иркен тормышта яшиләр. Монда нәрсә бар?.. Рәт бетеп бара яшәргә, жить итәргә. Әхмәтсафа, иртүк хәзер булып торыгыз, Шәмсия җиңгәң белән кызыл балчык, салам кайтара башлыйбыз, саман кирпече суга башларга кирәк. Болай йөрсәгез, быел кышка тагын өйсез каласыз. Без киткәч, белмим, сезгә ярдәм кулы сузучы булмас шикелле. Сәвиттән эләккән эш юк, талау ягын шәп белә, ярдәм итү ягын кайгырта башласа гына эше көяләп китә. Шәмсия җиңгәң, балалар үсеп җиткәнче, ташламыйм, дип, җан тартышканга гына китүне кичектереп тордым.— Фәтхулла бераз тын торгач өстәп куйды.— Иптәш егетләрең дә ярдәм итәрләр. Шулай бит, Саттар?

Саттар риза дигәнне белдереп баш какты. Ул арада Шәмсия килеп керде. Ап-ак катык тулы ташаягын өстәлгә утыртып, сиздермичә генә Фәтхуллага кагылып алды да түр якка кереп китте.

— Әйдәгез, энекәшләр, тамак ялгап алыйк,— дип, кашыкка үрелде хуҗа.— Аннан лапаска кереп, атны карарбыз. Нindирәк нәмәрсә микән ул?

Әхмәтсафаның зиһене тәмам таралган иде. Менә бит, шушы ат карагы Фәтхулланың ярдәме белән көн күреп яткан бит алар. Үзе дә, туганнары да. Начармы бу, яхшымы? Ул бигрәк тә Саттардан уңайсызлана. Ичмасам, аның алдында әйтмәскә иде. Комсомол диген... Ат карагы — кәсеп, имеш.

Саттарның исә дустының башында чабышкан уйларда бер эше дә юк, сыпырта гына катык белән ипине. Әллә тагын ел буе тамагына тәгам ризык капмаган.

— Әйдә, әйдә, җебеп утырма, Каеш, кашыкка үрел,— диде Фәтхулла. «Җебегән» сүзе аның күңеленә нык тия икән, башына шаулап кан йөгерде. Бу сүзне аңа Заһидә әйткән иде, әллә соң ул чыннан да бер җебегән, бәрәңге боламыгы? Бу очракта нәрсә эшләргә? Ә бит дөрес әйтә Фәтхулла, әгәр ярдәм итүче булмаса, алар быел тагын өйсез калалар, тагын кайсы кая таралып кыш чыгачаклар. Ул әкрен генә ипигә үрелде.

Ашап алганнан соң, ишегалдына чыктылар. Каргалыдагы күп кешеләрнекеннән аермалы буларак, Фәтхулланың ишегалды шактый киң, ихатасы төзек иде. Фәтхулла алдан, аның артыннан мылтык күтәргән Әхмәтсафа, иң арттан Саттар лапас эченә үттеләр. Фәтхулла лапас бүлмәләренең әле берсен, әле икенчесен ачып күрсәтте, гаҗәпкә каршы, атның

эзе дә юк иде лапаста. Фәтхулла, аптыраган кыяфәттә, ике кулын җәеп җибәрде:

— Ай күрде, кояш алды, энекәшләр. Аттан җилләр искән икән инде. Бигайбә, күрсәтеп булмады,— дип, ат тире исе сеңеп калган лапаста үзләрен генә калдырып чыгып та китте. Чыгып барышлый әйтеп кенә куйды:

— Каеш озак юанма, кояш күтәрелгәндә килеп җитәрбез. Бүгеннән эшкә башлыйбыз. Тегенди-мондый сүз кузгатып та йөрмәгез. Файдасыз сүздән дә кадерсез нәрсә юк дөньяда. Үзегез шаһит, монда ат-фәлән кермәгән, ахры. Сез күргән җайдак кем булгандыр — миңа караңгы. Анысын бер Алла белә. Минем бер катышым да юк ул эшкә...

— Ну иштек ишәк чумарын...— диде ачынып Әхмәтсафа.— Әйт, Саттар, син барысын да үз күзләрең белән күрдең, үз колакларың белән ишеттең. Нишлибез хәзер?..

Саттар, юкка хафаланма дигәндәй, кулын гына селтәп җибәрде.

— Оясыннан егылган чәүкә баласы шикелле тыпырчынма, дустым. Беренчедән, мин бернәрсә дә ишетмәдем; икенчедән, Шәмсияттәйнең катыгы бик шәп булды әле, шуңа күңелем булып тора; өченчедән, кайтышлый Рәхимгә кереп чыгам, бераз йокы туйдырып алабыз да сезгә өмәгә киләбез. Фәтхулла абзый дөрес әйтә, быелдан да калырга ярамый, өй җиткерергә кирәк. Ә ат мәсьәләсен оныт син. Тотылмаган карак түгел. Күреп торасың, без катык көтеп утырганда, Шәмсия абыстай аткарган чаптарны. Кая, ничек, анысын үзләре генә белә...

Шулай итеп, өй мәшәкатьләре белән көзгә дә килеп керделәр. Кырпак кар яуган көннәрнең берсендә Фәтхулла абый белән Шәмсия Хива ягына кузгалдылар. Озаткан чагында Бибкәй Шәмсияне кочаклап үкси-үкси елады. Аңа кушылып Шәмсия яшь түкте, Фәтхулланың да күзләре чыланды. Авыр аерылышу булды бу.

Әхмәтсафа исә кыш буе итек текте. Кече туганнарын мәктәпкә бирде, ничек тә кеше арасына кертү, белемле итү иде исәбе. Гомәрхан көн-төн эштә, тормыш ярыйсы гына җайланып китте сыман бу елда.

## XIII

Белемгә омтылуы көчле булгандыр инде Әхмәтсафаның, ел буе институтны, мөгаллимнәрне, сабакташ дусларын сагынып яшәде. Көннәр көзгә авыша башлагач, Гомәрхан белән киңәштеләр дә Әхмәтсафа укуын дәвам итәргә булды.

Институтка ул ашкынып килде. Шулай да бераз тартынган, ятсынган да кебек. Бу зур бинаның һәр ташы аннан

сорау ала кебек: «Һәй, егет, ел буе кая югалып тордың?.. Яңа тормыш төзибез дип кайларга гына барып, кемнәр алдында гына нотык сөйләп йөрмәдең. Ә үзең ни майтардың шушы бер ел эчендә? Монда чакта бик актив идең, институтта һәркемгә таныш, һәркемнең йомышы төшәрлек шәкерткә әйләнеп баруыңа да шаһит без. Синең өчен куанып туймый идек, менә сиңа мә — суга төшкән сыман юкка чыктың. Синең болай күздән югалуыңа барыбыз да пошаманга төшкән идек, әле дә ярый, менә янә ишекләрне ачып, белем йортына килеп кердең. Рәхим ит, югалып торуыңа үпкә-сапкабыз бетте, нык холыклы бул, егет бул! Белем алу — инә белән кое казу, бирешмә, иҗтиһад ит!»

Өске катка күтәрелеп барганда, каршысына таныш кызлар очрады. Алар инде җиткән кызлар, соңгы курста укыйлар. Туктап, шаярта төшеп, хәл-әхвәлләрен сорашмакчы булды.

— Миннән башка исән-имин яшәдегезме, кызлар? Ни хәлләр бар? Бу дөньяда яшәүләр ничек? — диде ул, уенынчынын кушып.

— Каршыда торма әле, бүкән, — дигән тупас сүзләр ишетте җавапка Әхмәтсафа. Аптырап, күзләрен зур ачып, кызларга карады да катып калды. Ни булган боларга? Шушы ике-өч баскыч үткән арада кызлар Әхмәтсафага төбәп тә, бер-берсенә дә нинди генә тупас, хәтта сүгенү сүзләре әйтеп бетермәделәр. Кая Нургали ага Надиев, Заһид Шәркый ни карый?! Мондый тупас сүзләрне тире-күн фабрикасының сасы бүлемтәләрендә эшләүче ирләрдән дә ишетергә туры килмәде аңа. Болар чыгырдан чыккан сыман кыланалар. Әхмәтсафа колаклары кызарганын тойды.

Тулай торак бүлмәсенә керде... Күп сабакташлары юк иде инде. Муса Казанга китеп барган, бу хакта, әлбәттә, Әхмәтсафа белә иде, бергә сөйләшкән, серләшкән чакларда үзе үк Мусаны Казанга, Тукай әйтмешли, театрлы, мәгърифәтле Казанга китәргә аз димләмәде. Гайшәгә хатлар язып торуын да белә. Казан Мусаны зурлап каршы алган. Рабфакта белем эсти, газета-журналлар белән элемтә тота, язучылар, зыялылар белән аралаша, китап чыгару артыннан йөри икән. Кыскасы, Мусаның хәлләре начар түгел. Дусты өчен сөенде Әхмәтсафа. Күп студентлар, Башкортстанның пайтәхете Стәрлетамактан Уфага күчерелгәч, анда китеп барганнар. Сәгыйть Агишев та Уфага киткән. Бу самими дустын бик сагынган иде, күрешүләр насыйп булмаган икән.

Дусларның кайсы кая таралып бетүен белгәч, егет бераз пошаманга төште. Шулай да иң аптыратканы — кызларның сәер кыланышы иде. Авыз ачып сүз әйтеп өлгермисең,

сиңа нинди генә әшәке сүзләр ишеттереп өлгермиләр алар. Алар өчен Әхмәтсафа ояла, үзләренең исләре дә китми, кисәтү ясап өлгермисең, начар сүзләр белән керендерәләр дә мөһим бер эш башкарган кыяфәттә китеп баралар. «Болар белән төзерсең яңа дөньяны. Белем учагы саналган бинада, әдәп-әхлакның тоткасы — педагоглар әзерләүче мәркәз саналган җирдә сафлыкның, гүзәллекнең, инсафлыкның гәүдәләнеше саналырга тиешле татар кызлары шулай кылансын инде...» Ул, форсат табып, бу хакта сыйныфташы Саимә белән сөйләшеп карамакчы иде, тегесе авызын гына ерды:

— Исең китмәсен ишәк б... Беребез дә алтын к... төшмәгән. Туфрактан яралганбыз, туфракка китәсе, китап сүзе генә сөйләп яшәп булмас инде.

Саимә белән сөйләшеп торганда, турларыннан басынкы адымнар белән чандыр гәүдәле чибәр бер кыз үтеп китте. Ул кызый Саимәнең сүзләрен ишеттеме, юкмы, анысы егеткә караңгы, әмма гәптәшенең авызын иләмсез ачып шаркылдап көлүенә оялып, керфекләрен аяк очына төбәп, тизрәк бу мәхшәрдән котылырга иде дигән кыяфәттә иреннәрен турсайта төшеп үтеп барышы егет игътибарыннан читтә калмады. Моны Саимә дә сизеп алды.

— Чибәрме? — диде, хәйләкәр елмаеп.— Икенче сыйныфта укый. Атбасардан килгән. Бик харап инде, әле бер егеткә дә күз салганы юк. Юашлыгың аркасында Заһидә белән дә борчагың пешмәде. Егет булса, ут булсын, ут булмаса, юк булсын. Ирләр ул, егеткәем, нык куллы булырга тиеш, сугып ексын, тартып торгызсын. Вәт шундыйларга тартыла кызлар. Бу кызыкай ипле күренә, Заһидә кебек кысыр өмет юллап йөрүче түгел. Сиңа нәкъ шундый кызлар кирәк тә бит. Танышып кара, бәлки, сине үз итәр чибәр туташ. Әй тәрбияле дә инде. Шундыйларны җенем сөйми, фәләннәрен фәлән итим...— дип такылдап та алды.

Кызларның бер-берсен уздырып яман сүгенеп, ямьсезләнеп йөрүенә гарык булды Әхмәтсафа. Гаҗәбе, моңа башка бер егет тә борчылмый кебек, кызлардан тупас сүз ишетсәләр, алардан өч-дүрт мәртәбә үткәреп, әшәке итеп җавап кайтаралар. Бу кадәр шакшы сөйләшүдән институтның затлы бинасы җирәнеп йөзен чытып тора, хәтта чарасызлыктан җиргә чүккән сыман иде.

Бер җай чыкканда, Зиннәттән бу хәлнең сәбәбен сорамый булдыра алмады.

— Моның белән Нургали абзый Надиев та, башка мөгаллимнәр дә көрәшеп карадылар. Әле дәрестә сүгенә башлаганнар иде, бәхетең, ул хикмәтләрне күрмәдең. Мөгал-

лимнәр ничә мәртәбә дәрес өзделәр, ничә мәртәбә җыелыш җыйдылар, тыешлы гына булмады. Җыелышка губкомнан Галинны чакыртып китерергә өлгерәләр «сүгенү оешмасы» кызлары. Бушка тегермән тартырга Галинга куш инде. Мөгаллимнәрне куркытып, аларны яман сүгеп, искелек калдыклары дип хәрәкәләп-куркытып бетерә дә губком исеменнән җыелышны оештыручыларга шелтә чәпи. Кулында власть булгач, нишләсә дә килешә, күпкә сузмый, җыелышны шунда ук ябып тарата һәм, зур эш кырган кыяфәттә, «сүгенү оешмасы» кызлары белән чыр-чу килеп кич үткәрә.

— Нинди «сүгенү оешмасы» ул тагын?

— Кызлар Галинның турыдан-туры җитәкчелегендә шундый оешма төзеделәр. Искелеккә каршы көрәшнең иң үтемле чарасы, имеш. Һәрхәлдә, шулай аклыйлар гамәлләрен. Аңа каршы чыгып азапландык, билгеле. Гайшә, Пәрваз, тагын берничә кыз, егетләр моңа каршы протест митингысы да оештырып карадык. Юк, үз туксаннары туксан, каһәрләрнең. Ә барысы да шул Галиннан, губкомның шыр надан бәндәсеннән башланды. Ул үткән ел институтта «яңа совет йолаларын гамәлгә кертү» түгәрәге оештырды. Беренче көнне үк яшьләргә ябырылды: имеш, без дөрес сөйләшмибез, советча аралашмыйбыз, мәхәббәтне дөрес аңламыйбыз. Бер-берең белән кешечә, матур итеп гәпләшү, аңлашу мещанлык дип бәяләнде. «Болай мулла кызлары кебек әдәпле аралашу — советча яшәү үрнәге була алмый»,— дип кистереп әйтте. Гади һәм үтемле сөйләшергә өйрәник дип, яшьләрнең башларын әйләндерә торгач, тәки үзенекенә иреште: кызлар тупас һәм хәшәб сүзләр өйрәнеп алдылар — бу өлкәдә түгәрәк эшчәнлеге нәтиҗәле булды. Егетләр кызларны да уздыра башладылар. Хәтта әшәке сөйләшү буенча сыйныфлар арасында ярышлар да ачтылар. Шулай, дускай, башкаларга ияреп үзгәрсәң, сине акыллыга санайлар, үзгәрмәскә маташсаң, шыр тилегә чутлыйлар. Сине әле акыллы дип әйтеп булмый, үзгәрергә уйламыйсың,— Зиннәт көлеп куйды.— Кызларның яннарыннан үтеп булмый, сүзләреннән тизәк исе килә башлады. Акыл җитми, авылдан җыелган инсафлы кызлар, егетләр «яңа йола» дигән булып шундый түбәнлеккә төшсеннәр инде. Ата-аналары ишетсә, акылдан шашарлар, билләһи.

— Болай булмый, егетләр,— диде Әхмәтсафа, тәвәккәл тавыш белән.— Чыннан да, берничек тә әлеге гыйбрәтне тыя алмадыгызмы? — дип кайтарып сорады.

— Дөресен әйтәм, без чарасыз идек. Галинны акылга утырта алмадык тәки. Губком исеменнән сөйли, кесәсендә — ре-

золюция. Анда акка кара белән: «Яңа совет йолаларына каршы төшүчеләрне институттан куарга»,— дип язылган. Авызны ачсаң, хәзер томалап куя Галин. Каршы килеп буламы губкомга?

— Тапкан, совет йоласы, имеш. Ул өйрәткән йола, горефгадәтләр белән барсак, ерак китәрбез инде.

Озакка сузмыйча, Әхмәтсафа Гайшә белән Саимәне ияртеп комсомолның губерна комитетына алып китте. Монда аны Оренбурда, Каргалыда яшьләр эшләрен оештыручы буларак яхшы беләләр иде, шуңа күрә ачыктан-ачык сөйләште. Егет губком җитәкчеләренә институтта гына түгел, гомумән, яшьләр җыелган һәр җирдә Галинның зарарлы «йолалары» тамыр җәюен, әгәр вакытында чик куелмаса, яшьләрнең көтелмәгән күңелсез хәлләргә тарып бетәчәкләре хакында дәлилләр китереп, кайнарланып аңлатып бирде. Җитәкчеләр эшнең тирәнгә киткәнлеген аңлап алдылар бугай, егет белән килештеләр, кичекмәстән мондый нәрсәләрне тыя башлау хакында карар кабул ителәчәгенә ышандырдылар.

Әхмәтсафа карар кабул ителгәнне көтмәде. Институтка кайту белән, Нургали Надиев янына кереп, институтның гомуми җыелышын җыйнарга рөхсәт алды.

Җыелышта исә мөгаллимнәр генә түгел, моңарчы башка фикердә булган күпчелек тә Әхмәтсафаны яклады. Мондый сөмсезлек, тупаслыктан барысы да гарык булганнар. Моңа кадәр Галинга каршы төшүчеләр булса да, эшне ахыргача җиткерүче булмаганга гына «яңа йола» шул дәрәҗәдә институтта тамыр җәеп өлгергән.

Ахырда җыелыш шундый карар кабул итте: «1.Шушы көннән соң Галинны институт бинасына кертмәскә. 2. «Сүгенүчеләр оешмасы»на кергән студентлар, барлык мөгаллимнәрдән, сабакташларыннан гафу үтенеп, тупас мөгамәләдән баш тартырга тиешләр. 3. Яңадан мондый фактлар кабатланса, андый студентларның алга табан институтта белем алуын махсус комиссия карарга тиеш». Сүз генә булып калмасын өчен, шундук комиссия дә төзеп куйдылар. Комиссия составына Гайшә, Зиннәт һәм моңарчы Әхмәтсафа күзенә бер генә күренеп калган Рабига Сарымсакова, ягъни чибәр һәм тыйнак Атбасар кызы да керде. Комиссия рәисе итеп Әхмәтсафа сайланды. Шул көннән башлап егетнең күңел түрендә якты йолдыз кабынды. Бу йолдызның сүнмәс-сүрелмәс исеме — Рабига атлы иде. Рабига да егетне бер күрүдә үз итте. Шул көннән башлап ике яшь йөрәк бер-берсен уйлап типте, бер-берсен сөеп яшәде.

## XIV

Рабига, Рабига... Әйе, Әхмәтсафаның күңелен биләп алган йолдыз ул. Шушы кыз белән танышкан ике еллап вакыт эчендә егет аңа шулкадәр  ияләште, әгәр дә бер көнне Рабиганы күрми торса, яшәүнең яме, ризыкның тәме китә, дөньясы асты өскә килә, үзенә  урын табалмый  интегеп бетә.

Җәйге каникул чорында абыйсы Гомәрхан белән хәллерәк кешеләргә ялланып печән чабуда эшләде, ә уе — Рабигада, кыз кайтып киткән Атбасар якларында йөрде. Кояш та Атбасар ягыннан чыга төсле тоела иде, төн җитеп, истә-оста юкта күк түрендә пәйда булган чекерәеп янган йолдыз да Рабига яшәгән яктан һавага чөелгәндер, ул гына да түгел, аның җем-җем итеп янып торуы үзе үк Рабиганың якты карашы төсле тоела башлый. Каяндыр Җаек аръягыннан тәгәрәп чыккан түп-түгәрәк ай да кызның үзеннән нурлар җыйгандыр да, хәзер менә якты нурларын мул итеп Әхмәтсафа яшәгән Сакмар буйларына таратадыр кебек тоела. Егет үзенең нинди халәттә йөргәнен үзе дә аңлап бетерә алмый. Дөньясы үзгәрде, моңарчы яшәүнең ямен бөтенләй күрмәгән икән лә ул, кылган һәр эшендә, һәр гамәлендә Рабиганың да катнашы бар сыман. Егеткә тормыш гаме иңде. Гамьсез кеше — ямьсез кеше. Мәхәббәт белән өретелгән гамь исә, гүзәл гамь егетне алга әйди, аны һаман-һаман биеклекләргә җилкендереп тора иде. Әхмәтсафа Рабига белән танышкан ике ел эчендә олыгаеп китте сыман, һәр гамәлен, үзе янында булмаса да, Рабига күреп торадыр, сүзен ишетәдер, бәя бирәдер кебек. Ул сабырлана төште, кылган һәр эшен мәгънәле итәргә тырышты. Яшереп торасы юк, егетнең йөрәгендә мәхәббәт уты кабынды. Инде Әхмәтсафага Рабигадан башка тормыш юктыр шикелле тоела. Гаҗәбе шул: егет белән кыз аулакта икәүдән-икәү калып бер-берсенә ярату, мәхәббәт сүзләрен сөйләгәннәре юк моңарчы. Тик үзләре генә түгел, бөтен институт, хәтта бөтен кала белә кебек — алар бер-берсенә үлеп гашыйк, алар бер-берсеннән башка яши алмыйлар. Күпләрнең күз алдында туган, аңлашу-газаплардан азат саф, якты мәхәббәт иде ул.

Бергәләп «әдәплелек кичәләре» үткәргәндә, аралары тагын да якынайды. Ныклап танышулары да шул кичәләрдә булды бугай. Рабига, һәрхәлдә, Әхмәтсафага шулай тоелды, мандолинада искиткеч оста уйный икән. Кылларны чиртүче медиаторны кысып тоткан озынча, аксыл бармакларына, җылылык бөркелеп торган (егеткә шулай тоела) кулларына карый да Әхмәтсафа дөньясын онытa. Менә Рабига «Салкын чишмә» көен уйный. Егет үзен шунда ук урман ала-

нында итеп хис итә. Алан читенә тезелешкән ямь-яшел гөләп куаклары, аллы-гөлле чәчәкләр, шул аланның түрендә чикләвек куаклары каплап алган биек яр астыннан челтер-челтер агып яткан чишмә. Бу илаһи күренешне мандолина кылларыннан түгелгән моң аермачык күз алдына китереп бастыра: чишмә сулары көмештер, ул суның салкынлыгы, сафлыгы, ул суның иреккә чыгып йөгергән уенчак җан иясе шикелле гөрли-гөрли шаярып-чабулап мул сулы инешкә табан ашыгулары, ул суны иренгә тигезүгә җанның чистарып китүләре, күңелнең очынулары, яшәүнең мәңгелегенә инану, аның кабатланмас мизгелләрдән җыелган төс-манзараларын, ямен тою — кыз уйнаганда менә шулар уйга килә. Ул арада моң егетне үзе белән хыял дөньясына алып китә. Менә Рабига, чишмә суын учларына алып, Әхмәтсафага эчертә, имеш. Тешләре камаша Әхмәтсафаның, бөркүлектән кысылган тыны киңәя, дөньясы яктыра. Кыз аңа карап тыенкы елмаеп тора, ә күзләрендә сихри нурлар уйный. Әхмәтсафа үзендә тыелгысыз дәрт сизә, әллә нинди яхшы гамәлләр кыласы, илләрне, җирне үзенең матур эшләре белән сискәндерәсе килә. Рабиганы да гаҗәпләндереп, дөньяны яңгыратып кычкырасы иде: әй, кешеләр, җирем, күгем, мин әле бик матур эшләр, гүзәл гамәлләр кылачакмын! Чөнки мине һәрдаим дәртләндереп, көч биреп торучы гап-гади җир кызы, җанымны яулап алган шаһинәм — Рабигам бар. Их, сез аның гүзәллеген күрәсез микән, мин кичергән тойгыларны сизә аласыз микән, гомумән, дөньяда ул яшәгәнне беләсез микән?! Юктыр, белеп бетермисездер, күрмисездер, мин янган сихри-рәхәт утларда янмыйсыздыр, киресенчә булса, җир, әйләнүдән туктап, аңа мөкиббән калыр иде, кошлар, сайраудан туктап, Рабиганың уйнавын гына тыңлар иде, бер мәлгә чишмәләр агуыннан туктап торыр иде, барысы да кызның сихри моңнарына әсир калырлар иде дә табигатьнең шушы илаһи затына гына табынып яши башларлар иде. Яхшымы бу, әллә сәер, гайре табигый хәл булыр идеме, егет аны уйлап бетерә алмый, аның җилкәсенә кемдер кагылып, колагына пышылдый:

— Егет, дөньяңны оныттың бит. Рабигаң уйнап бетерде, чиратта сәхнәгә кем чыга? Халык көтә, чыгып әйт, син бит кичәнең хуҗасы!

Гайшә икән. Татлы уйларыннан аерылып бетмәгән хәлдә, Әхмәтсафа сәхнәгә, декламация сөйләргә чыгып китә...

Институтта укыган соңгы елы шундый сихри халәттә үтте аның.

...Ленин үлгәч, комсомолның губерна комитеты тәкъдиме

буенча, ТИНОда укучы күп кенә яшьләр, комсомоллар инде, әлбәттә, «Ленин призывы» дигән хикмәтле исем астында коммунистлар партиясенә әгъзалыкка кандидат итеп кабул ителделәр. Әхмәтсафа Дәүләтъяров — унтугыз яшьлек егет — бу адымының мөһимлеген, тормышында нинди урын тотачагын уйлап җиткердеме, юкмы, анысына үзе дә ныклап торып җавап бирә алмас иде, әмма гомуми шаукым аны үз эченә бөтереп алып кереп китте, ул инде шушы ташкын көченә тиң инанулар ихтыярында иде. Егет үзен һич икеләнүсез яңа дөнья төзүчеләрнең иң алгы сафында баручы яшь көч дип уйлый, гаризасына да шулай дип язды: «Дөнья пролетариатының җиңүе, илебезнең чәчәк атуы өчен гомеремне дә кызганмам!» Бирә, һичшиксез, бирәчәк гомерен Әхмәтсафа. Әгәр дөнья пролетариаты, ил фәкать аның гомере бәрабәренә иң гүзәл тормыш — коммунизм кора ала икән, нигә бирмәскә гомерне?! Билгеле, ул яңа, бәхетле Киләчәкне бергә-бергә төзеп, анда сөенеп-шатланып бергәләп яшәсәң яхшырак булыр иде дә, гариза укыганда әнә шул «гомеремне дә бирәм» дигән сүзләргә аеруча нык игътибар итәләр шул. Күрәсең, комиссия әгъзаларына ике дә уйламыйча гомерләрен фирка хисабына тапшыручылар кадерлерәк. Күп, бик күп кадерледән кисәк кенә кадерсезгә әйләнгән гомерләр кирәк фиркагә дөнья байгышларын рәхәткә чыгару өчен.

Гомәр абзый егетнең үз гомере хисабына фиркагә керүен өнәмичә чәпчеп алды алуын.

— Шулай да фиркагә керүеңнең асыл максатын ничек аңлатасың? — дип сорады ул Әхмәтсафадан, кискенрәк итеп.

Моңарчы йомшак кына сөйләшә торган картның шулай зәһәрләнеп китүенә сәерсенә төшеп, егет җавап кайтарды:

— Социализм төзү, халыкны рәхәт тормышка тиендерү…

— Аннан ни кылмак буласыз бу «рәхәткә тиенгән» халык белән?

— Коммунизм төзү…

— Анысы ни-нәмәрсә була инде?..

— Анысымы?.. Ни инде — барлык кешеләр дә тигез, мул тормышта яшиләр. Дөньяда хәерчеләр, байлар дигән аерымлану булмаячак. Болай кешене җиде тиресен салдырып эшләтү, көчләү булмаячак. Һәркемнең үз ихтыяры…

— Һи җүләр баш, җүләр баш! Һәркемнең үз ихтыяры белән эшләвенә калгач, нәмә булып чыга соң инде ул? Юк, татар холкына коммунизм дигән нәмә туры килми, һич кенә дә туры килми. Эше барның, ашы бар, ди татар. Татар беркайчан да кеше күзенә карап яшәмәгән, кулы эшкә ятып тора аның. Ә менә урыска коммунизм дигән нәмә мач килә. Бу халык, турысын әйтик, ялкау. Бар байлыгы — башка

кавемне талап табылган мал. Урыс халкын кызыктырып була эшләмичә ашау белән. Ашау дигәндә хәзер сикереп төшә ул мич башыннан. Димәк ки, болай булып чыга — бүтән кавемнәр баш күтәрмичә эшләргә тиеш, шул чагында, чыннан да, урыс туганнарымыз коммунизмда яши башлар. Әгәр барып чыкса... Синнән әлегә эш вә гомер таләп ителә. Коммунизм дигән нәмә әкият ул. Тиле Иван турындагы әкиятне Лилин дигән бәндә икенче төрле итеп кенә язып биргән. Шул әкияткә ышанып йөрүче сезнең кебекләрнең булачагын алдан күреп язган ул аны. Ни генә әйтмә, акыллы, хәйләкәр бәндә ул. Ялганның кеше ышанмастаена гына ышанганнарын белеп ут йөгертә...

Әхмәтсафа шундый бөек төшенчәләрне көлке дәрәҗәсенә төшереп аңлатырга маташкан Гомәр абзыйга үпкәләр дәрәҗәдә чыгып китте ул чакта.

Рабига нигәдер губком кыставына бирелмәде, «әле мин мондый зур эшкә өлгермәдем» дип, «Ленин призывы»ннан битараф рәвештә төшеп калды. Әмма Әхмәтсафаның партиягә керергә омтылышына каршы килмәде — «дөньясы шул инде» дию белән чикләнде.

Партиягә керү уен-муен түгел, иң элек бер ел дәвамында кандидатлык стажы үтү шарт иде, шушы чор эчендә үзеңнең партия эшенә тугрылыклы булуыңны расларга да тиешсең әле. Моның өчен, һичшиксез, партия поручениеләрен үтәргә кирәк. Әхмәтсафага тире-күн эшкәртү фабрикасы эшчеләренә партия, хөкүмәт карарларын аңлату бурычын йөкләделәр. Килгән саен эшчеләр клубында концерт оештырырга кирәк, монда да алар гел Рабига белән бергә булдылар. Клуб каршында «Татар бүлеге» оештырып, төрле бәйрәмнәрдә эшчеләр арасыннан сәләтлеләрен сайлап алып, концертлар, спектакльләр куя башладылар. Ару-талуны белмичә үтәде фирка кушканны. Булачак яшь әгъзасы эшеннән партия канәгать булырлык иде югыйсә, әмма алда тагын бер сынау кичәргә туры киләчәк икән әле. Монысын башына да китереп карамады Әхмәтсафа. 1925 елның апрель аенда педагогия институтын тәмамлыйм, кулга диплом алып, зур тормыш юлына аяк басам дип йөргәндә, партиянең губерна комитеты юлламасы буенча яшь коммунистларны Урта Азиягә совет хакимияте урнаштыру эшенә ярдәм итү өчен җибәрергә дигән фәрман җиткерделәр. Исемлектә Әхмәтсафа да бар иде.

Губком секретаре, калын күзлекле хәрби киемле кеше, Әхмәтсафа Дәүләтъяров, Саттар Ишбулдинга дивар янына тезеп куелган шактый йончылган урындыкларга утырырга ишарә ясап алгандай кыланды да, егетләрнең утыру-утыр-

мауларына да игътибар итмәстән, бераз түшәмгә карап торды. Тирән итеп сулыш алганнан соң, инде аларга кадәр дистәләрчә мәртәбә сөйләп, ятлап бетергән сүзләрен тезәргә кереште:

— Иптәшләр, мөһим эш — партиянең җаваплы заданиесен үтәү йөзеннән чакырдым сезне. Белгәнегезчә, совет хөкүмәте Советлар иленең барлык почмакларында да ныклап аякка басты, бөтен илдә яңа тормыш төзелә. Халык партиягә ышана, эшчеләр сафы ныгый, партия сафларына меңнәрчә яшь көрәшчеләр килә. Ленинның васыятьләре соңгы иҗегенә кадәр үтәләчәк! Моңа хәзер беркемнең шиге юк. Бүгенге көндә хәлиткеч фронт — Урта Азиядә, иптәшләр. Аңлыйсыздыр, анда совет хакимиятен урнаштыру җиңел булмады. Кызганычка каршы, милли республикаларда совет хөкүмәте ныклап аякка баса алмый. Анда дошманнар әле корал ташламадылар. Алар мәкерле. Алар әле һаман үзләрен көчле итеп сизәләр. Иң нык аяк чалган нәрсә — халыкның наданлыгы, дошманнарга сукырларча иярүе. Муллаларның, контрреволюцион көчләрнең, байларның һәм буржуаз милләтчеләрнең йогынтысы гаять көчле. Белемле кадрлар җитешми, бөтен Урта Азия буйлап басмачылар, бандитлар йөри, алар җирле халыкны кылыч йөзендә, наган мушкасында тоталар. Авыр хәл, бик авыр, иптәшләр. Ә Урта Азиясез совет хакимияте юк, дөнья пролетариатының җиңүе юк. Менә шундый шартларда Үзәк Комитет сезгә ышана, сезгә таяна. Урта Азиядә яшәүче миллионнарча үксезләр коммунистларга, ягъни сезгә (губком секретаре нигәдер «безгә» димәде) мөрәҗәгать итәләр: «Килегез,— диләр алар,— төзеп бирегез яңа тормыш, аң-белем бирегез, өйрәтегез,— диләр.— Аннан без өлгереп җиткәч, кире туган якларыгызга кайтырсыз, завод-фабрикаларда эшегезне дәвам итәрсез, укуларыгызны тәмамларсыз, безнең иксез-чиксез рәхмәтләребезне тоеп яшәрсез!» — диләр. Моңа ни дип җавап бирә алабыз. Фәкать утвердительно, иптәшләр! Фәкать эш белән генә җавап бирә алабыз. Каршы килә алмыйбыз һәм моңа бүген хакыбыз да, хокукыбыз да юк. Без бит партия солдатлары!

Бу сөйләшү апрель аенда булып, күп тә үтмәде Әхмәтсафага Хива өлкә комитеты карамагына җибәрелүе хакында белешмә тоттырдылар. Егет юлга хәзерләнә башлады.

Белешмәне күргәч, Рабига бер сүз дә дәшмәде, бары керфек очларына яшь тамчылары эленде. Кызны мондый хәлдә беренче мәртәбә күргән Әхмәтсафаның җаны кузгалып куйды. Хәзер инде ул Рабиганың үзе өчен никадәр газиз, никадәр якын икәнен бөтен барлыгы белән тоеп алды, моңарчы гашыйк булып, иләсләнеп йөрүләре күңелнең очыну-җилке-

нүе, якты хисләр кабынган мәлләр генә булган икән. Чын хисләр эчтәрәк, һәм Рабиганың, һәм егетнең күңел түренә яшеренгән, бикләнгән булган. Менә хәзер аерылышу якынлашкан көннәрдә, хисләр дулап өскә бәреп чыктылар, аларны яшереп торасы юк, Әхмәтсафаның нинди сәфәргә чыгасы билгеле, авыр, үтә куркыныч аның сәфәре. Аулакта очрашкач, Рабига сүзсез генә егетнең муенына сарылды һәм мышкылдап елап җибәрде. Егет, кызны юатырга тырышып, кулын иңнәреннән алып, сак кына күкрәгенә кысты, Рабига исә тыелырга уйламый да, елавы елау...

— Елама, Рабига,— диде Әхмәтсафа, күңелендәге авыр ташны кузгатырга теләгәндәй еш-еш тын алып.— Исән-имин кайтырга, тагын күрешергә язсын.— Ул беренче мәртәбә кызның яшь чылаткан кайнар битләреннән үбеп алды.— Көтәрсең бит?

— Көтәрмен...— диде Рабига, егеткә сыенып.

Китәр вакытлар зур тизлек белән якынлаша тора. Егетнең күңелендәге баштагы иләслек, ашкыну сүрелә төште. Ул Рабиганы агабзыкай — Гомәр абзый белән таныштырырга да өлгерде. Аннан, бер генә көнгә булса да, Каргалыга кайтып килде. Монда барысы да исән-имин, йорт гөр килеп тора. Гомәрхан өйләнергә, туй итәргә җыена икән. Энесенең шундый вакытта ерак сәфәргә китеп баруына ул һич кенә дә риза булмый, тәртәгә тибеп азапланды:

— Нәмә калган сиңа анда? — диде ул кайнарланып.— Үзләре теләгән тормышны үзләре төзесен. Менә мин ничә ел окопларда бет симертеп яттым. Халыкны бәхетле итәм, имеш. Берәрсе килеп рәхмәт әйткәне бармы? Шунда алган авырулардан берүзем саргаям менә... Йөрмә дүнгәләк кебек, җил уңаена себерелеп. Кайт та эшкә башла. Укуың җитәрлек, иншалла, югалмассың.

Әхмәтсафа авырлык белән генә инде мәсьәләнең губерна җитәкчелеге дәрәҗәсендә хәл ителүен, кире уйларга юлның калмаганлыгын аңлата алды.

Абыйсы үз эше белән каядыр чыгып китте. Әхмәтхан белән Бибкәй сабактан кайтып җитмәгән иде, ул, эче пошып, ян бакчадан әйләнеп керергә булды. Бакчаны тәртипкә китерергә өлгермәвенә үкенеп, күптәнге янгыннан кара көеп, тырпаеп утырган алмагач кәүсәләренә — кара кисәүләргә карап торды. Күңеле тулды, күзләренә яшь тыгылды. Әхмәтсафа бакча түрендә бер алмагач кәүсәсенең тернәкләнеп килүен күреп алды. Яшел яфраклы ботак өскә үрмәләп маташа. Ботакта күз явын алырлык ап-ак чәчкә балкып тора. Егет, шуңа сабыйларча сөенеп, чәчкәдән бик озак күзен ала

алмый торды. Шул чагында болытлы язгы көн яктырып, тирә-юнь нурланып киткән кебек булды.

Икенче көнне таң белән юлга кузгалды ул. Кичке поездга өлгерергә кирәк. Аны Рабига озатып калырга тиеш... Болдырдан төшүгә игътибар итте — мул итеп иртәнге кырау төшкән, аяк өсте шакырынлап каткан. Егетнең йөрәге тибүеннән туктап калды сыман, аяклары ирексездән бакча ягына атлады. Менә кичә генә сокланып торган алмагачы... Алсу төстәге чәчәкләрне боз элпәсе каплап алган. Алар шул элпә аша сүрән иртәгә боек кына багалар кебек. Юк, ачыргаланып кычкыралар, салкыннан, боздан аралап алуны үтенеп ялваралар, иңриләр кебек. Әхмәтсафа йөгереп барып кайнар тыны белән боз элпәсен эретеп төшерде. Чәчәк таҗыннан җанны чеметтереп салкын тамчылар тәгәрәште. Кайчандыр әткәсе әйткән сүзләр исенә килде: «Табигать ялгышмый ул, кешеләр ялгыша. Саташып таң атмый, бәндәләр саташа...» Ул әкрен генә чыгу ягына борылды. Табигать тә ялгыша, ахрысы. Менә бит шундый авырлыклар, газаплар аша терелергә, җимеш бирергә азаплана алмагач, ә... иртәсен кырау суккан чәчәген. Табигать үзе тудырганны үзе һәлак итә, кешеләр дә аннан калышмый, һаман көрәш, һаман дау дип хыялланалар. Күпме уйланса да, яшәешнең асылын аңлый алмый әле Әхмәтсафа...

# Икенче китап



# ӨЕРМӘ

…Бүгенгедән сезгә онтылмаслык
Зур бер тарих мирас калачак.

*Һади Такташ*

## I

…1930 елның салкын гыйнвар иртәсе…

Чулман өсләп сыек рәшә сыман томан күтәрелә. Яңа ел башына кадәр ишле карлар явып, көннәр буранлап торды да, кинәт кенә җылытып, җепшетеп җибәрде. Атна чамасы шулай булды. Карлар чын-чынлап эри башлады дигәндә генә, кыш яңадан бар ихтыярын, бар гайрәтен үз кулына алды, сансызланып маташкан идегез, менә күрегез инде, алайса, дигәндәй, янә буран котырды, аннан чатнама суыклар башланды.

Чаллыдан чыкканга чирек сәгать вакыт үтмәде, туры айгырның сырты ак бәскә төренеп өлгерде. Юл бозлы, шуңа күрә олаучы, кашсыз бүрек кигән олы яшьләрдәге чандыр гәүдәле агай, атын бик куаламаска тырыша — ат хөкүмәтнеке, кантон кәнүшниеннән бирелгән, аяк-тоягын имгәтеп кайтсаң, көт тә тор, мәхкәмәсез-нисез Минзәлә төрмәсендә ике-өч ай яткырып, сохари кимертеп чыгарырлар. Яңа блачның талканы коры. Казан кунагына ике дөнья бер морҗа, чыптага төренеп, печәнгә күмелеп утырган да, дәшми-тынмый, үз уйларына йомылып тик бара. Керпе кебек. Болай үзе, кала кешесе булса да, кышкы юлга чыкканын белгән тагын, калын киенгән, аягында да шәп олтанлы киез итек. Казаннан килгән вәкилләрне күргәне бар агайның, кайберсе бигрәк юка киенеп килә: әллә кышкы юлга чыккан, әллә сәхрәгә сәйранга җыенган. Чанага менеп утыруга тотына тынгысызланырга, тотына боргаланырга — шул арада моңа суык бабай ике куллап чытырдап ябышырга да өлгергән, димәк ки… Бичара мосафир чәнчеп-чәнчеп ямчыга да карап ала. Әйтерсең аны юлга җыйнап-төйнәп ул чыгарып җибәргән. Андый чакта ямчы кая керер тишек тапмый, үзен карасынмы, олауны кайгыртсынмы, әллә вәкилне катырып үтермәс өчен чара күрсенме — валлаһи, якты дөньяга бүген туган сабый шикелле көйләтмәкче үзләрен кайбер вәкил дигәннәре. Эшең

ямчылык кылу булгач, берни эшләр хәл юк, һәммәсен дә кайгыртырга туры килә. Атына утырткан икән, адәм баласын исән-имин тиешле урынга илтеп җиткерү өчен ул, ямчы, җавап бирә бит. Кыюлык та, тәвәккәллек тә, осталык та кирәк әлеге эштә. Үткән дәвердә ямчы аты куганнар өчен какшамас канун булган әлеге хакыйкать бүген дә үзгәрмәгән, киләчәктә дә үзгәрергә тиеш түгел. Агай иркенрәк тын алды, бу егет, болай яшь күренсә дә, җитди кешегә охшаган, көйләтеп, юкка-барга чәпчеп, җанны җәфаламас шикелле.

Кичә, кояш баер алдыннан, Чаллы кантуны каршына килеп туктап, ис җыярга өлгермәде, каршысында шушы егет пәйда булды. Минзәләдән үзен алырга килгән ямчы икәнен белгәч, елмаеп, ике куллап күреште дә, төнне Чаллыда үткәрергә туры киләсен әйтеп, эш-мәшәкать дилбегәсен үз кулына алды: агайның атын-тунын кантун кәнүшниендә калдырып, үзен кунакханәгә урнаштырып мәш килде. Йокы бүсәргә һәвәс түгел икән, агай уянырга өлгермәде, егет иртүк агай артыннан килеп тә җитте, бергәләп чәйләп алдылар, аннан инде сәфәргә җыена башладылар: атны идарә каршына туктатып, чана башына китаптыр-мазардыр төяп азапландылар. Болай булса, чанада үзләренә урын да калмас, Минзәләгә кадәр алмашлап җәяү кайтырга туры килмәгәе дип курка да башлаган иде, бәхетенә, Казан кунагының йөге төялеп беттеме, әллә ямчының уйларын аңлап, төяү эшләрен үзе үк туктаттымы — җиңелчә агач чемодан тотып, канткомның ярым түгәрәк ишегеннән килеп чыкты, ямчы аты белән мәшәләнгән чакта, урын көйләштереп, чанага менеп тә утырды.

Юлга иртүк кузгалу ярый ул, кичкә, Ходай юлны уң кылсын, кайтып та керерләр өяз каласына. Ямчы, электән ишеткәләгәне булса да, һич кенә дә «кантун» дигән сүзгә күнегә алмый, ияләнгән «өяз» сүзе җанына ничектер якын сыман тоела иде. Татарстан җөмһүрияте төзелгәч, өяз сүзен кантунга алыштырдылар да куйдылар. Хәер, элекке өязне дә чәчкәләп, таратып бетерделәр. Мәскәү кушкан, диделәр. Үзебезнең дәүләтебез булды дип лаф ордылар, үзебезгә үзебез хуҗа дип тә җибәрәләр иде. Митинглар оештырып, башны күп әйләндерделәр инде. Шул бер «өяз» сүзен дә калдыра алмагач, нинди хуҗа инде син илгә?.. Һә, бик хуҗа булырыең да, кулыңда көч — гаскәр юк бит синең, ие бит. Сәгыйдуллин кулында да юк иде, Байчурин да, буш кул белән килеп, буш кул белән китте. Дөнья йөзендә гаскәре булмаган нинди дәүләт, нинди җөмһүрият бар ди?! Үзләре шәп егетләр иде болай. Тик тел белән тегермән тартып хөррият яулап булмый шул. Күп телеңә салынсаң да килешми, Ижау ягыннан егерме мылтыклы солдат килсә, беттең диген инде, һавага бер гөрселдәтсәләр, минут эчендә дәүләтең дә

юк, җөмһүриятең дә юк, телең дә кыскарып калыр... Шул мылтыклы егерме солдат блач булып куячак бөтен өязеңә. Мәскәүнең сүзе Минзәлә өчен дә, Казан өчен дә канун. Күп шыбырдый алмассың, иеме, вәкил иптәш? Кычкырып сорарга тел кычыта да, килешеп бетмәс шул, килешеп бетмәс. Кайтып кергәч ГПУга җиткерсә... Ул ГПУ дигән нәмәрсә туры Мәскәүгә карый, ди бит. Әле тел озайтмасаң да... советка каршы элемент дип, авылы-авылы белән төяп китерәләр халыкны Минзәлә төрмәсенә. Кайберәүләрен шунда ук чыгарып аталар да икән. Иннә лилләһи вә иннә иләйһи раҗигун... Бичараларның ни гаепләре булгандыр яңа блач каршында. Юкса үтә череп чыккан байлар Колчакка ияреп әллә кайчан бу яклардан эзләрен суыттылар. Хәер, бай кеше, акчалы кеше беркайчан, бер җирдә аптырамас ул. Ямчы агаең да чегән арбасыннан төшеп калган дегет чиләге түгел, егеткәем, күрмәде түгел, күрде — бу дөньяда акыл алдан йөрми, акча алдыра, ул башлап сүз әйтә... Шулай да байлар белән сөйләшү, эш йөртү җиңелрәк иде. Менә шулар хакында рәхәтләнеп гәпләшеп кайтасы иде дә. Юл кыскарыр иде, ичмаса. Ярап бетмәс шул Казан вәкиленә ташыган уйларыңны чыгарып түгү, килештермәс...

Атның бер җайга юыртуына иярләшкән Әхмәтсафа Дәүләтъяров исә үз уйлары белән мәшгуль. Әле ул Минзәләдә ниләр эшләргә тиешлеген чамалап та бетерми. Декабрь урталарында Татар коммунистик университетының соңгы курсында укучы студентларны җыеп алдылар да, үзләренең ел башыннан урыннарда һаман да ныгып җитә алмаган совет хакимиятенә булышлык күрсәтү өчен, егермебишмеңчеләр сыйфатында кантоннарга китәчәкләре турында әйттеләр.

Партия ячейкасы бюросы әгъзасы буларак, Әхмәтсафа әлеге эшләрнең уртасында кайнады, студентларны кантоннарга бүлгәндә, Казан тирәсендә калырга җае бар иде — исемлекне үз куллары белән төзеде, әмма иң ерак кантонга — Минзәләгә — дип язып куйды Дәүләтъяров фамилиясе турысына. Ул мизгелдә күңелендә бер генә уй тулганып алды, укуны тәмамлап, диплом алырга ярты еллап вакыт калып бара, бераз гына сабыр итсәләр булыр иде югарыда утыручы түрәләргә, югары белемле һөнәрмән булып эшкә башлау кулайрак та булыр иде гамәли якны исәпләгәндә, әмма сәяси вазгыять шуны таләп иткәч, нишлисең?..

## II

Сталин, күзен кыса төшеп, дача тәрәзәсеннән бакчага карап торды. Нәрсә тота аны тәрәзә каршында болай озаклап, һич кенә дә аңлый алмый. Югыйсә сәркатип кертеп биргән почтаның әле чиреген дә карап чыга алмады. Көн инде кич-

кә авыша башлаган, хәл итәргә тиешле көндәлек мәшәкатьләр хәттин ашкан.

Татарстаннан килгән телеграмманы укыгач, дәрте сүрелде аның. Беренче карашка, өлкә комитеты сәркатибе Разумовның телеграммасына ул сөенергә генә тиеш иде — Разумов, республиканың барлык кантоннарында да егермебишмеңчеләрнең ныклап эшкә керешүләрен хәбәр итеп, даһи юлбашчы Сталин дөрес һәм гадел күрсәткәнчә, Татарстанның быелгы язны йөз процент күмәкләшкән хәлдә каршы алачагына катгый ышандыра. Телеграммадагы «Сталинның, партиянең установкасын тулысынча үтәү — өлкә комитетының намус эше һәм бу мәсьәләдә бернинди чигенү дә булмас!» дигән сүзләрне нигәдер ошатмады ул. Соңгы вакытта аңа күмәкләштерү эшендәге бөгелешләр хакында да хәбәрләр килеп ирешә башлады. Сталин үзенә килеп ирешкән хәбәрләрнең никадәр нечкә иләктән иләнгәнен аңламаслык хәлдә түгел. Инде күмәкләшү урындагы надан, күрәкараучы җитәкчеләр аркасында гарип форма алган икән, нишләп бу эш Сталин исеме белән бәйләнә? Шул ук Татарстан партия оешмасы кылган гамәлләрнең барысы да ал да гөлме? Ә бит һәр эш юлбашчы исеменнән башкарыла: Сталин күрсәткәнчә, Сталин установкасы... Бер гөрәнкә уңыштан да башлары әйләнгән бу наданнарның телен тешләтәсе иде... Тулысынча җиңү булгач кына дөреслек, гаделлек дип авыз чайкарга мөмкин булачак. Нindидер хәстәрлек күрмичә ярамый, һәрнәрсәдә өлгерлек күрсәтү кирәк. Разумовның телеграммасы шундый зирәк фикергә китерде: тиз арада «Правда»га мәкалә әзерләп бирергә кирәк. Исеме дә шәп: «Уңышлардан баш әйләнү». Разумов та, башкалар да дөрес эш алып баралар: йөз процент күмәкләштерү мәҗбүри. Тик акцентларны үзгәртә төшеп...

Аның йөзендә сизелер-сизелмәс яктылык уйнап алды. Бакча түрендәге миләш агачы һаман кызыл җимешләре белән тулышып тора. Гадәттә, бу вакытта җимешләрдән җилләр искән була, игътибар иткәне бар — декабрь башларындагы дымык бер иртәдә каяндыр көтүе белән миләш чыпчыгы килеп чыга да кып-кызыл җимеш сырып алган агачны минут эчендә «чишендереп» тә куялар. Сталин — «төн кошы», иртәләрен йоклап үткәрә, ә менә нәкъ шушы көнне иртүк аяк өстендә була һәм иң сәере — шушы әрсез, талымсыз кошлар өеренең бакчада минутлык вәйран чигүенә аерым ләззәтләнү белән карап тора. Ни өчен икәнен үзе дә аңлата алмый. Быел исә нигәдер соңладылар кошлар. Әллә исәпләре бөтенләй килмәскәме? Гыйнвар үтеп бара түгелме соң инде. Ул шулай уйлап бетермәде, миләш агачын кызыл түшле кош чирүе сырып та алды...

Нигәдер җиңел булып китте. Юк, дөнья күчәренең әйләнешен үзгәртер көч юк җир йөзендә. Һәр пешкән җимеш өзеп алынырга тиеш, хәтта вакыты үтә төшсә дә. Җәмгыять үсешендә, иҗтимагый фикердә «күмәкләшү» дигән татлы җимеш күпләрнең күзен кыздыргандыр кыздыруын, әмма бу җимешнең өлгерүен көткән меңләгән әрсез өер, йолкыш чирү барлыгын бер генә минутка да онытырга ярамый шул. Күз ачып йомганчы илеңне туздырып атачак бу өер. Ил белән үзеңне дә. Тир түкмичә бәхеткә, муллыкка ирешү хыялыннан да мәгънәсез омтылыш юк. Менә шушы куркынычка юл куймаска кирәк, өерләрне ачыкларга, әйдәүчеләрен эзләп табарга һәм берәм-берәм мәйданнан алып атарга кирәк. Еракта балкып торган миләш җимеше кебек — бар иде, мизгел эчендә юкка чыксын. Иң мөһиме шунда, моны беркем дә белми дә калсын. Аның үзеннән башка...

Разумовны Татарстанга җибәреп дөрес эшләде ул. Татарлар хәтәр халык. Акыллы, еракка карап эш йөртүчән, бер-берсенә юл куймый торган үзсүзле, үҗәт халык. Шушы сыйфатлары аркасында Милләт эшләре халык комиссариатын җитәкләгәндә, аның канына аз тоз салмады бу кавем кешеләре. Күз алдында үз-үзләренә гаҗәеп ышанган Солтангалиев, Вахитов сурәте пәйда булды. Җанын туктаусыз нидер кимергән кыяфәттә йөрүче Ибраһимовның үртәгеч карашын янә тоеп, тәненә салкын йөгерде. Тагын бер егет истә калган — анысы мөселман полклары төзим дип хыяллана иде. Тиктормас, революция идеаллары белән тәмам адарынган егет иде ул. Әмма ул чакта ук Сталин сизеп алды, егет шулай ук еракка карап эш йөртә иде бит — әгәр Ленин, ахмак Троцкий коткысына бирелеп, татарлардан гына торган мөселман гаскәрләре төзергә ирек бирсә, ни белән төгәлләнер иде микән революция дигәннәре! Ярый әле бу хәлне вакытында туктатып кала алды Сталин, аның тарафыннан Ленинга тиешле сирәк рәхмәтләрнең берсе дә шуның өчен иде: Усмановның, менә бит ничек, хәтта фамилиясе хәтердән китми нәләт егетнең, нинди ният белән йөрүен аңлатып биргәч, Ленин үзе дә урыныннан сикереп торып, зыр килеп бүлмәсен әйләнеп чыкты. Татарларга үз кулларың белән гаскәр төзеп бир, дәүләт бир. Аннан нәрсә?.. Шул сәгатьтә үк төзелә башлаган мөселман полкын фронтка җибәрүне таләп итеп, Фрунзега телеграмма сукты һәм шуның белән идеягә нокта куелды. Әйе, татарлар белән тезген һәрчак кыска булырга тиеш. Ул чакта да шулай фикер йөртте Сталин, хәзер исә бигрәк тә. Көчле халык, рухи тамыры сәламәт сакланган халык. Сәләтлеләрне тарих мәйданына ыргытып кына тора. Чүпләп кенә өлгер — күзне, зиһенне алдап янып торган ачы җимешләрне.

...Егерменче еллар дәвамында Татарстан хөкүмәте җитәкчелеге Мәскәү басымына каршы кискен көрәш алып барды. Бу көрәш ни белән тәмамланыр иде, фараз итүе авыр, әмма Мәскәү өчен шунысы әһәмиятле иде: җитәкчеләрнең үзләре арасында да фикер каршылыгы чыга торды, төркемнәр барлыкка килде. Һәр төркем, каршы якны фаш итеп, Мәскәүгә хат артыннан хат юллады. Сталин татарларның абруй алдында гына баш иеп игә килә торган халык икәнлеген аңлаган иде инде. Татарстанда барган фикер көрәше, үчегү-бәхәсләр, әгәр дә ки ул үз куллары белән Солтангалиевне юлдан алып ташламаса, булмас та иде, чөнки Мирсәет көчле шәхес, акыллы һәм зирәк, абруйлы җитәкче, татарлар аңа, һичшиксез, буйсыначак, хәтта күзенә генә карап торырлар иде. Моңа, бәлки, Сталинның артык исе дә китмәс иде. Совет властеның тәүге елларында милли республикалардагы тынычлык Мәскәү өчен үтә мөһим нәрсә иде. Әмма иң куркынычы да шунда — Солтангалиевнең күзенә карап торучы бер татарлар гына түгел шул... Милли сәясәт өлкәсендә илдәге төрки халыклар алдында Солтангалиевнең абруе шулкадәр үсте, хәтта берзаман Сталин үзен дә ул халыклар алдында Солтангалиевнең күләгәсе сыман гына хис итә башлады. Моңа юл кую — дилбегәне кулдан ычкындыруга бәрабәр һәм ул, бар зиһенен җыеп, Мирсәеткә каршы җәтмә үрә башлады, җаен китереп, фирка исеме белән Солтангалиевне юлдан чөеп ыргытуга иреште дә. Авыр булды Мирсәеткә каршы көрәшкә чыгу, әмма фирка, халыклар, ил алдында сәяси яктан гына түгел, хәтта җисмән яктан да үзеңне саклап калуның башка юлын күрмәде ул. Сталин көрәшнең иң хәйләкәр әмәлләрен эзләп тапты, тозакның иң шәпләрен куйды Солтангалиев юлына һәм тегесе, татарларга хас ышанучан зат, килеп капты да. Мирсәетне үз абруен үстерү өчен йөз процентка файдаландым дип исәпли ул, шуңа эчтән генә сөенә. Татарстанга исә Белоруссиядән сыналган большевик Мендель Маркович Хатаевичны җибәрде. Хәйләкәр яһүд эшкә авырыксынып керешсә дә, татарларны тиз кулга алды, куандырганы шул: Солтангалиевкә каршы куя алды ул татар коммунистларын. Сталин ялгышмады, Хатаевичның абруе тәэсирле булды, өлкә комитетында чагыштырмача тынычлык урнашты, милләтчелек учагы сүрелде. Үзәк Комитетка яла, әләкләрнең Татарстаннан аз килә башлавы шуңа ишарә иде. Татарлар сәер халык, берсе чак кына өскә үрмәли башласа, хәзер буза куптаралар. Теге бәхетсезне, урыныннан тартып төшереп, тизәктә аунатмыйча тынычланмыйлар, моның өчен вакыт та, көч тә кызганмыйлар. Татарның иң яраткан эше — әләк язу. Мәскәү гомер-гомергә бу халыкның тар күңелле булуыннан файдаланып эш йөртте. Итәк

астыннан ут йөгертү өчен иң кулай мохит татарның акыллы башлары арасында. Татарның булдыклы егетләре бер-берсен таптый, изә. Үзләре үк бумаклап үтергән улларын күз яшьләре белән юып ләхеткә иңдерә... Ахырдан югалган кавемдәшләрен кызганып нәгъръләр ора, аһ итә, чәчләрен йолкыйлар... Татарның акылы төштән соң. Сталин менә шундый халыкта асыл егетләр — зирәк сәясәтчеләр, икътисадчылар, язучы-каләм осталары үсеп чыга алуына чынлап аптырый иде. Ул үзе Татарстанда булып үткән һәрнәрсәне җентекләп күзәтеп барды, кирәк тапса, кичекмәстән юнәлеш бирә килде.

1927 елның ноябрь аенда партиянең унөченче өлкә конференциясе, «буржуаз милләтчеләргә һәм группаларга каршы көрәш» шигаре астында үтеп, әлегәчә милли хисләр йогынтысыннан арына алмаган татар зыялыларын янә бер кат туздырып атты. Күпчелеген илдән үк сөрделәр. Рәхимсез кыландылар татарлар. Татар дөньясы умарта оясыдай гөжләп алды да тынып калды. Сталинның күңеленә шик йөгерде. Шикне раслап, Казан ягыннан янә әләкләр ява башлады. Ныклап барлый башлагач, шул билгеле булды: революциягә кадәр җитлеккән татар зыялыларының зур күпчелеге исән-имин генә яшәп яталар икән. Куылганнар, туздырылганнар, тапталганнар, изелгәннәр, әмма исәннәр! Идел буенда, Уралда, Себердә, Урта Азиядә генә түгел, Мәскәү, Ленинградта да җитәрлек иде алар. Нинди яшәүчән халык!.. Шулар, баш күтәреп, тирә-юньгә күз салганнар да бераз өскә калка башлаган кавемдәшләрен батыру эшенә керешеп киләләр икән. Димәк, тамырлар исән, куркыныч үтмәгән, әле катылык, тәвәккәллек җитми... Сталин мондый мәсьәләдә башлаган эшне ярты юлда калдыра торганнардан түгел, хәйләкәррәк һәм сакланыбрак эш йөрткән Хатаевичны Самарага күчереп, аның урынына Казанга Михаил Осипович Разумовны җибәрде. Эшчеләр арасында чарланып өлгергән, дуамал холыклы, бераз кылтык та, әмма ВКП(б) Үзәк Комитеты алдында гаять абруйлы Разумовның Сталин алдында йөзен җиргә ормас өчен барысын да эшләргә хәзер икәнлегенә иманы камил иде юлбашчының.

## III

Вазгыятьтән чыгып, дөресен әйтик, Хатаевичның Татарстанга килүенең файдасы булмады түгел — ызгышып ятудан туктап, киләчәк хакында уйлый башлау кирәк, татарлар өчен берәү дә килеп эшләмәс, оҗмах төзеп бирмәс, дигән карашны җирле җитәкчеләргә яхшылап сеңдерде ул. Татарлар торган саен яңа тормыш йөген ныграк тарталар, элекке кебек, юк кына эш өчен дә Мәскәүдән ярдәм сорап, шаулап,

чаң сугып йөрмиләр, һәрнәрсәне урында хәл итәргә омтылалар. Иң мөһиме — үзара бугазлашып ятудан башканы белмәгән, күпчелеге революциядә, гражданнар сугышында катнашып, ат өстендә кылыч болгап йөргән чакта кылган каһарманлыклары һәм шулар өстенә кайбер оештыру сыйфатлары чагылып киткән өчен генә җитәкчелеккә үрмәләгән дистәләрчә надан коммунистлар урынына яңа чорда тәрбияләнгән, белемле кадрлар хәзерләү эше юлга салынды. Казан югары уку йортларына кытлык кичерми, аларда татар студентларының саны сизелерлек артты, техникумнар, һөнәри-техник белем бирү мәктәпләре ачылды. Төрле өлкәләрдә сибелеп көн күргән өметле татар яшьләре Казанга тартыла башлады, хәзерлекле татарларны җитәкчелек эшенә яки тагын да алга табан белем эстәргә чакырып китерү колач җәйде.

Шушы әйбәт шаукымга Әхмәтсафа Дәүләтъяров та килеп эләкте, партиянең Хорезм өлкә комитетында җаваплы инструктор булып эшләгән егерме бер яшьлек егетне, үз гаризасы нигезендә, Казанга, Татар коммунистик университетына чакырып кайтардылар.

...Әхмәтсафа, уйларыннан аерылып, йөзен чытып куйды. Көтмәгәндә көйле генә барган уку өзелеп куйсын инде, ә?.. Пошмас җирдән пошар эчең...

Әмма партия карарын санга сукмаска хакы юк аның. Яшь кадрларны авылларга җибәреп, сыйнфый көрәш шартларында чыныктырып алу турындагы фикер яңа булмаса да, бөтен кискенлеге белән ВКП(б)ның унбишенче съездында көн тәртибенә килеп басканын яхшы белә ул.

1927 елның декабрендә Мәскәүдә үткән бу съезд илнең крестьян тормышын тамырдан үзгәртүгә нигез салды. Съездда аерым хуҗалыкларны бетереп, кулакны сыйныф буларак юкка чыгару, авыл хуҗалыгын коллективлаштыру турында карарлар кабул ителде һәм шул карарларны үтәү йөзеннән авылларда нинди генә гамәлләр кылынмый да, нинди генә хикмәтләр эшләнми шушы ике ел эчендә. Әхмәтсафа ишетеп тора — бу гамәлләр арасында хилафлары да җитәрлек иде. Ямчы агайның ара-тирә авыр сулап алуының сәбәбе нәкъ шушы сәяси хәлләр аркасында түгел микән? Ялыкты авыл туктаусыз куалау-ашыктырулардан. Бу хакта университетта Разумовский, Ишков кебек профессорлар да әйткән иде. Артык каударлану беркайчан да җүнлегә китерми. Разумов һаман риза түгел, эшне кызу тотарга куша, утызынчы елның язын авыл тоташ коллективлашкан хәлдә каршы алырга тиеш дип ашыктыра һәм һәр чыгышында моның партия, Сталин установкасы икәнлеген искәртеп, үзенең бу хакта юлбашчыга партия вәгъдәсе бирүен дә әйтеп, чигенергә юл юклыгын да сиздереп куя.

1929 елның көзендә ВКП(б)ның Татарстан өлкә комитеты, кантоннардагы партия һәм совет органнарының җитәкчеләрен җыйнап, махсус киңәшмә үткәрде. Киңәшмә барышында ике сүзнең берендә урыннарда кадрлар мәсьәләсенең катлаулы булуы телгә алынды. ВКП(б) Үзәк Комитетының ноябрь пленумы карары нигезендә авылларга шәһәр эшчеләре, интеллигенция арасыннан егермебишменчеләр җибәрүнең мәҗбүрилеген искә алып, утызынчы елның башында ук Татарстан авылларына дүрт йөзләп кеше җибәрергә тиеш дип табылды. Әхмәтсафаның шушы егермебишменченең берсе сыйфатында Минзәләгә барышы да инде.

— Менә бусы Әҗмәкәй дигән авыл була инде...— диде ямчы агай, зур гына авылның урамына барып кергәч.

Әхмәтсафа, уйларыннан арынып, читәннәрен кар көртләре күмеп китә язган тар урамга күз ташлады. Ике атлы кара-каршы килсә, ничек юл сабыша торгандыр, анысын олаучылар үзләре генә белә. Кар көрте аша да сизелеп тора: өйләр, ниндидер шомлы хәл буласын көтеп торгандай куырылып, җиргә сеңеп үк утыралар. Салам түбә, түбәне тишеп чыккан морҗа башларына төпсез балчык чүлмәк кигертелгән, морҗалардан сүрән генә аксыл төтен саркыла. Тешкә сылаша торган төче төтен. Яшереп торасы юк, җанга тансык ис аңкый төтеннән. Әхмәтсафа туып-үскән моннан ерак-еректагы Оренбур ягындагы Каргалы авылында да шундый ук ис тарала иде дөньяга — кизәк, салам яккан якларда шундый ис була.

— Авылда әле һаман тормыш көтүләре җиңелдән түгел бугай...— диде көттереп кенә Әхмәтсафа.— Мин бу якларда беренче мәртәбә. Танышлыгым юк, шулай да чамаларга була. Үзем дә сала малае...

Ямчы рәнҗегән төсле, теш арасыннан берничә сүз сыгып чыгарды:

— Хәерче, алама инде безнең яклар, туган.— Аннан, күңелдәгесен нигә яшереп торам соң әле дигәндәй, тавышын күтәрә төшеп, тезеп китте.— Яңа тормыш дигән булалар... Яңасы кайчан төзелер, белгән юк, әлегә булганын җимерү дә туздыру. Яшь чагында никрутлар «Ват, җимер коймасын, юл өстендә тормасын» дип җырлыйлар иде. Яшь-җилкенчәк ни җырламас, чынга алучы юк ие аларның сүзләрен. Ә бу хөкүмәт чынлап тотынды туздырырга, ни кыланганын аңлап бетереп булмый, туган.— Ямчы агайның бүәсе ерылды, зарланыпмы зарлана.— Азап чигә халык, бә-әк интегеп җан асрый. Чистый, киямал йөрәккә төштеләр, һаман тынгылык юк халыкка...

— Кантунда ни хәлләр бар соң? Нигә тыныч түгел халык?

Ямчы, әллә айдан егылып төштеңме дигәндәй, сәер генә Әхмәтсафага карап алды. Чынлап сорый, ахрысы, чыраенда төчеләнеп маташу билгесе юк.

— Ни бит, туганкай, әйтсәң — сүз, төртсәң — күз дигәндәй, хөкүмәт иман тоткасы булган хәзрәтләргә юл бирми башлады. Халыкны диннән, иманнан яздырып нәрсә күрмәкчеләрдер... Инде зур хәзрәтләрне җыеп бетерделәр, хәзер мәчет картларына тотындылар. Халык бә-әк рәнҗи моңа, апай.— Минзәлә ягында үзләреннән кече кешегә «апай» дип дәшкәннәрен ишеткәне бар иде Әхмәтсафаның. Ул көлемсерәп куйды. Әмма агайның сүзе җитди нәрсә хакында бара иде.— Ә бит сәвит үзе урлашырга, таларга өйрәтә халыкны, шуңа юл куя. Мал-мөлкәтле бәндәләрне җыеп төрмәгә ябалар да куялар. Милке кая китә аларның? Совет тирәсенә елышкан җыен әтрәк-әләм йома малны. Хәзрәт үзе төрмәдә, гаиләсен өйдән куып чыгарып, ихатасына аркылыны торкылы салырга иренгән хөрәсәннәр кереп оялый аның төзек йортына. Шул да булдымы дөреслек?

— Халык белән киңәшләшеп эшләнмимени болар? Партия бит башбаштаклыкка юл куймаска куша.

— Бер дә рәт чыгардай түгел синнән — китап сүзләре сөйләргә һәвәс икәнсең, туганкай. Нинди партия кайгысы булсын ул хәчтерүшләрдә, кулга гомердә күрмәгән мал килеп эләккәч соң...

Агай чаманы онытып җибәрде.

— Саграк, абзый,— диде Әхмәтсафа, тәмам кызып, бар куәтенә кычкырып сөйләнеп барган ямчыны тыярга теләп.

Ямчы көтелмәгән үҗәтлек күрсәтте, Казаннан килүче мосафирдан шикләнмәскә мөмкин икәнлеген, аның кеше сатмаячагын абайлап өлгергән иде булса кирәк, үз туксаны туксан:

— Йөрәк яна шул,— диде ул ачынып.— Минем куркыр чаклар үткән инде. Уемдагы — телемдә. Баткан аяк чылана дигәндәй, ярты сүз әйтмәс борын авызны томаларга ашыкма, апай. Үзең халыктан сорарга дисең...— Әхмәтсафа чамалап алганча, агай һич тә надан бер сала мажигы түгел иде.— Минзәлә кантунына караган Иркәнәш дигән авылдан мин үзем. Узган атнада туганнарымны җыеп алдылар да «кулак» дип, төрмәгә китереп япканнар. Мине Алла саклады, олауда калдым. Авылга кайтырга да шикләндерә, кайтып керсәм, ни булыр тагын... Нинди кулак булыйк без? Һәркайсыбыз үз хуҗалыгында үз көче белән көн күрә, җитеш тормышта яши идек. Шул гына... Имеш, күмхуҗга каршы без. Кем «күмхуҗ» дип йөри? Җыен суыгаяк, сәлкәү, ялкау. Алар кереп оялады сәвиткә. Без тир түгәргә тиеш, тегеләр ашарга. Ашамый торсыннар әле, иеме,

бахбай...— Ямчы нәрсәдәндер өркеп, читкә каерырга маташкан атына дилбегә кагып алды.— На-а, малкай, үтеп барабыз Әҗмәкәен дә...

— Бу авыл миңа таныш,— диде Әхмәтсафа, нидер исенә төшеп.

— Безнең якларда булганым юк, дисең үзең...

— Булганым юк, анысы хак сүз. Татарстанда гражданнар сугышы тарихын өйрәнгәндә укыган идем. Бу авыл тирәсендә зур сугышлар булган акларга каршы.

— Китапка язалардыр инде. Безгә анысы караңгы,— диде ямчы теләмичә генә.

— Алда тагын нинди авыллар бар ?

— Калмыя, Малтабар, Күзкәй, Югары Байлар...— дип тезеп китте ямчы.

— Кызык исемнәр. Мин туып-үскән Оренбур ягында да авылларның исеме матур: Биккол, Нәүрүз, Йөзекәй, Мостафа, Сакмар... Һәр егерме-егерме биш чакрым саен татар авыллары. Тезеп чыккан кебек. Үзем — Каргалыдан,— дип, туган авылын янә бер мәртәбә искә аласы итте.

— Ишеткәнем бар. Ямчы авыллары. Яшь чагында күп йөрелде, сезнең якка да барып чыктым. Бохарасына кадәр барып җиттем. Кызыл мал ташыдым мин Фәттах байга. Якын тирәдә бер бай иде. Ул да юкка чыкты. Туздырды сәвит, туздырды тормышны.

Әхмәтсафа дәшмәде, «Бохара» сүзен ишеткәч, нигәдер ямансулап, үз уйларына йотылып бара бирде. Уйлары аны еракка-еракка алып киттеләр.

* * *

Революциядән соң сугыш китергән бәла-казадан, җимерекләрдән, буталыш һәм ачлыктан тәмам хәлсезләнгән халыкның исән калуда бердәнбер һәм соңгы өмете — Урта Азиягә барып урнашу иде. Ташкент, Бохара яклары телдән дә төшмәде ул чакта. «Ташкент — икмәкле шәһәр!» Әлеге сүзләрне иң беренче кем әйткән, кайда әйткән, кайчан әйткән — анысын уйлап торыш юк, Ташкент каласы күпләрне ымсындыра, үзенә тарта иде. Агылды татар ул якка, агылды. Агыла торды, күбесе, комга сеңгән су сыман, хәбәрсез югала торды. «Ачы дәвернең шәүкәтсез елларын шул якларда үткәрдем, заманага төс иңгәч, кире туган-үскән якларга кайттым әле» дип сөйләнгән кешене Әхмәтсафаның ишеткәне дә булмады диярлек. Күпмесе юлда кырылган киткән халыкның, күпмесе анда юкка чыккан, күпмесе, исән калып, шунда гомер кичерә — кем санап баккан аны...

Алар гына җитмәгәндер, яңа хөкүмәт тә аз тырышмады:

партия куша дип, татарның аңлы, фәһемле яшьләрен куды Урта Азиягә. Әхмәтсафа шундый «бәхетле»ләрнең берсе иде. Әүвәл аның кебек йөзләгән яшьләрне Бохарага җыйдылар, аннан тиешле кәгазьләр, мандатлар, юлламалар тоттырып, төрле вилаятьләргә* җибәрә тордылар. Бөтен эш хәрбиләр кулында, һәрнәрсә хәрбиләрчә ярым-йорты, ашыгыч эшләнгәнгә, Әхмәтсафа Бохарада үткән ике-өч көн эчендә юньләп ни шәһәрне, ни мондагы тормышны карый-күзәтә дә алмады. Шунысы сәер — Урта Азиягә сәяси-хуҗалык эшләрендә ярдәм итәргә җибәрелгән яшьләр төркеме белән аралашкан түрәләрнең зур күпчелеге янә дә татарлар булып чыкты. Җирле халыктан булган түрәләр исә юк дәрәҗәсендә аз иде. Әхмәтсафада шундый тойгы уянды — төрле яктан җыелган, белемнәре, тормыш тәҗрибәләре төрле булган шушы килмешәк кавем үз туган җирендә кайчандыр бөек мәмләкәтләр төзегән, дөньяга мәшһүр галимнәр бүләк иткән үзбәк халкына оҗмах төзеп бирә алырмы?.. Үзбәкләр көчкә-коралга каршы торып-торып та баскынчылар чирүеннән котыла алмагач, барысына кул селтәп, ни майтарсагыз майтарыгыз инде, анда безнең эшебез, гамебез юк дигәндәй, читтән генә күзәтеп торалар сыман.

Бохарада юлламага мөһер, тамга җыеп чабулап йөргәндә, көтмәгәндә Заһидәгә, ТИНОда укыган үткен-чая сабакташ кызга тап булды Әхмәтсафа. Мондый чакта күзгә ак-кара күренми, тар, ярым караңгы коридорда аңа бер хатын-кыз заты нык кына бәрелеп үтте, әмма каршысына болай әрсез төстә килгән үтә арык, эсседә, җилдә янып кара-чутырга әйләнгән хатын-кыз затына күз дә салмаган иде. Ике-өч адым үткәч, үрсәләнгән тавыш ишетеп, үзе дә өнсез калды:

— Әхмәтсафа?! Син түгелме соң, малайкаччаем?.. Әстәгым...

Әхмәтсафа шып туктап калды, артка әйләнеп карарга өлгермәде, кыз аның муенына килеп тә сарылды:

— Син бит бу Әхмәтсафа! Син... син...

Кайчандыр җаныннан артык күргән кешенең таныш чалымнарын шәйләп алуга, Әхмәтсафаның тез буыннары йомшарып китте.

— Заһидә!.. Каян килеп чыктың? — диде ул, кипшенгән телен көч-хәл белән әйләндереп.

Кыз үз кыланмышыннан оялыпмы, егеттән читкәрәк тайпылды, балчык сылап шомарткан коридор стенасына сөялде һәм арыган тавыш белән:

— Таныдың тагын...— дип мышкылдап елап җибәрде.

Шулкадәр газиз, тансык һәм кызганыч тоелды кыз. Егет

---

* *Вилаять* — өлкә, губерна.

чарасыз хәлдә Заһидәнең җиңелчә калтыранган иңсәсенә сак кына кагылып алды.

— Тынычлан, йә инде...— Үзенең дә тавышы калтыранып чыга иде.— Тау белән тау гына очрашмый, диләр... Әле дә исемә килә алмыйм.— Кабат сорамыйча булдыра алмады.— Каян килеп чыктың син бу җәһәннәмгә?

— Оҗмах юллап инде, оҗмах эзләп...— диде Заһидә, сулкылдавын басып.— Мин, ятимә кызга кайда булсын инде оҗмах...— диде ул әрнеп.

Әхмәтсафа ТИНОда укыганда көн дә очрашып, аралашып яшәгән сабакташының тормыш хәлләрен бөтенләй белмәвенә аптырап, кайтарып сорады:

— Ятимә? Әти-әниең юк идеме синең?..

— Мин Ташкентка киткәч, ачлыктан, тифтән үлеп беткәннәр. Беркемем дә калмады минем.— Кызның тавышы ерактан, тау-ташлар артыннан иңрәп чыккан сыман тоелды.

— Хәлләр шулай дигән...— Әхмәтсафа, көтелмәгән очрашудан кузгалган дулкынлануны, хисләр өермәсен басарга теләп, үзенең монда җәйге ял чорында эшләргә, үзбәк дусларга совет хакимияте төзүдә булышлык күрсәтергә җибәрелгәнен сөйләп алды.

Заһидә сүрән генә елмайды.

— Һи-и, җүләркәем, ике-өч ай каникул чорында ни кырмакчы буласың? Монда килгән һәркем шулай инде. Башта ике айга дип җибәрәләр, аннан өч-дүрт айга калырга кыстый башлыйлар. Шулай йөри торгач, айлар, еллар үткәне дә сизелми кала. Син дә ике-өч елсыз ис-акыл җыя алмассың, үтә дә китә ул вакыт дигәнең.

Сораша торгач, егет Заһидә хакында шактый күп нәрсә белеп өлгерде. Ташкентта медсестралар хәзерли торган курсларны тәмамлап, Бохара янындагы бер вилаятьтә эшләгән икән. Инде ике ел, ди.

— Мондагы халыкны күрсәң, Әхмәтсафа,— диде ул, бик зур яңалык әйткәндәй тавышын әкренәйтеп.— Ничек үлеп бетмиләр алар, ике ел араларында яшәп, тәки аңлый алмадым. Дөньясын бет баскан. Корчаңгы, бизгәк, трахома — бу нәмәкәйләргә шулкадәр ияләшеп беткәннәр, аларны авыру дип тә белмиләр. Туктаусыз бала табалар, исәбен-санын алучы юк, туа торалар, үлә баралар, бала җанын чебен урынына да күрмиләр. «Ходай бирде, Ходай алды» дип, бит сыпырып куялар да, вәссәлам. Исән калганы үсә инде. Алары — таш та тимер. Салкын да алмый, кызу да сукмый. Кислотага ташласаң, аннан да исән-сау чыгарлар. Вәт халык дисәң дә халык!

— Табигый сайланыш хикмәте,— диде Әхмәтсафа көлемсерәп.

— Нинди сайланыштыр, чуртым белсен,— диде Заһидә, битараф тавыш белән. Хәзер инде аның килеш-килбәте ТИНОда укыган чактагыга охшап калды. Шушы ярым караңгы коридорда кызны танымыйча үтә алырына Әхмәтсафа ышанмас та иде хәтта.

— Син кая билгеләндең? — дип сорады Заһидә, күзләрен зур итеп ачып.— Башың ике булмаса, ычкын, кач син. Ни калган монда, әнә үзбәкләр үзләре төзесен үзләренә кирәк тормышны. Мин гарык, җитәр, Казанга китәргә йөрим менә...— диде, көтелмәгән ныклык белән. Бу инде Заһидә, холкы бер генә мыскал да үзгәрмәгән Заһидә иде.

— Казанга? Ничек?..— Егет тәмам аптыраштa калган иде.— Мин Үргәнечкә китәм. Шунда билгеләндем...

— Иртәрәк килмәдең бит,— дип көлеп куйды Заһидә. Егетнең шулай үрсәләнеп алуы аңа ошап китте бугай.— Бергә-бергә күңеллерәк тә булыр иде. Әйтәм бит, монда килеп эләккәч, син теләгәнчә ансат кына китү юк ул, егетем. Өермәгә килеп капкан кебек инде син. Тиз генә ычкына алмыйсың... Мине дә өч кенә айга, практикага дип җибәргәннәр иде. Курсларда аз-маз укытып, укол кадарга, җәрәхәт бәйләргә өйрәттеләр дә әнә бара торган юлың, диделәр. Нинди генә авыруларны күрмәдем. Хирург та үзем, терапевт та, акушер да, балалар табибы да булырга туры килде вакыты белән.— Әхмәтсафа ул санап киткән нәрсәләрдән, дөресен әйткәндә, бернәрсә дә аңышмады. Аңа калса, ак халат киеп, хастаханәдә йөргән һәркем табиб. Заһидә мактанып та алды.— Яшерен-батырын түгел, үкенмим,— диде, бераз һавалы тавыш белән,— Мәскәүдән, тагын әллә кайлардан килгән зур табиблар кул астында да эшләдем. Алар биргән белемне миңа бер институт та бирә алмас иде. Барысын да җибәрәләр инде Урта Азиягә, барысының да ярдәм итәсе килә мондагы халыкка, һәммәсе бу халыкны агартырга тырыша. Үзбәкләрнең генә исләре дә китми. Ничек яшәгән, шулай яшиләр. Алар үзләре безне кара халыкка, аңгыра ишәккә чутлыйлар әле.

Бая Әхмәтсафа әйткән сүзләр исенә килеп, егеткә акыл бирергә тотынды.

— Үргәнече дә шул, башкасы да шул. Сак йөр, теләсә кая илтеп тыкма башыңны. Кышлакларда халык бик әйбәт күренә болай, тик белер-белмәс көе араларына кереп, телеңә ни килсә, шуны сөйли башласаң, хәзер тукмап ташларлар. Алай гына булса... Ленинны яраталар, «безнең кебек диһкан булган» дип кенә җибәрәләр. Башкаларын белмиләр дә, беләселәре дә килми. Басмачылар, фәлән-фәсмәтән дип авызыңны да ачма. Алар өчен басмачылар — без, ягъни совет хакимиятенә эшләүче теләсә каян җыелган халык.— Заһидә үгет-

нәсихәтем күпкә китте диптер инде, шаяра төшеп, Әхмәтсафаның җиңеннән тартып куйды.— Сүз бозау имезә. Миңа поездга өлгерергә кирәк. Әйберләрем иптәш кызымда... Аларны алам да поездга йөгерәм,— дип хушлаша башлады.

Әхмәтсафа, баштагы соравына җавап ишетмәгәч, янә сүз кузгатты:

— Казанга дисең... Уйлап сөйлисеңме, уйнапмы? Кем көтеп тора сине анда?

Заһидә ачылып китте.

— Ә-ә...— диде сузып кына,— әйтмәдеммени соң әле. Рабфакка укырга керергә гариза язып җибәргән идем. Чакыру килде. Укырга дисәң, монда бик карыша алмыйлар. Әйтәм бит, ярты ел җибәрүләрен сорап йөрдем. Һич кенә хәлгә кермиләр, баш катырып тик йөрттеләр шунда. Үзем дә бирешмәдем тагын. Әткәй, мәрхүм, әйтә торгание, син, кызым, ләтчә белән бер, дип. Ләтчәсе нәрсәдер, күргәнем юк, тычкан тота торган бер җәнлек бугай шунда.— Заһидә, сер әйткәндәй, янә тавышын басты.— Мин бит Гайшә белән хат алышып тордым. Оренбурдагы хәлләрнең барысын-барысын да беләм.— Күзләрен елтыратып, бертын Әхмәтсафага карап торды.— Синең дә, егеткәем, кызың бар икә-ән инде. Ниһаять, үзеңә тиңне тапкансың... Рабига исемле, бик матур, итагатьле кыз, дип язды Гайшә. Гайшә кадәр Гайшәгә дә ошагач, безнең ише генә түгел инде.— Йөзенә уфтану билгеләре сибелде.— Минем булмады инде тиңем, табалмадым,— диде ул, кулын селтәп.— Кем кирәктер миңа, нәрсәгә ашкынамдыр — үзем дә белмим. Тиңеңне табу — бәхет бит ул, Әхмәтсафа. Меңнәр арасыннан үз тиңеңне сайлап алу җиңел түгел шул. Хисләр акылны томалый да куя, каһәр. Оренбурны искә төшереп, елап чыккан төннәрем аз булмады. Үткәннәрне кире кайтарып булса икән...

Әхмәтсафа кызарганын тойды, маңгаена тир бәреп чыкты шикелле, ирексездән битен кул аркасы белән сөртеп сөйләнеп алды:

— Әле кая сиңа болай сөйләшергә. Япь-яшь башың белән, дим... Егетләрең күләгәдәй тагылып йөри торгандыр артыңнан.

— Синнән башка бер күләгәм булмады,— дип ярып салды Заһидә. Шулай ачыктан-ачык әйтүенә бераз кыенсынып, тотлыгып куйды.— Син... син... әй, барып чыкмады инде,— диде ул, янә кулы белән җилләнеп.— Язмагандыр, әйеме, Әхмәтсафа, малайкаччаем...— Ул сөйләшүне һаман да шаярту рәвешендә алып бармакчы иде дә, үзе дә сизми калды, күзләреннән яшь атылып чыкты.

— Такташ...— дип, уйламастан, кызның йөрәк ярасына тоз салды Әхмәтсафа.

— Такташын әйтерием...— диде ачу белән Заһидә.— Тотарсың аның койрыгын. Ә шулай да мин аны Ташкентта эзләп таптым,— дип җанланып китте кыз. Заһидәнең күзләрендә очкын уйнап алды. Шулай сәер янып-елтырап торган күзләрне беренче мәртәбә күрүе иде егетнең, бер мәлгә мәзәксенеп куйды. Заһидә исә поездга ашыгуын да онытып такылдый бирә.— Яшьләр клубында чыгыш ясый дип ишеткәч, соңгы акчама чәчәкләр сатып алдым да очтым шунда. Такташның сәхнәгә чыгып басуы булды, атылып мендем дә бирдем бер кочак чәчәкне. Үзем каушый-каушый пышылдаган булам: «Мин — Заһидә... Оренбур... ТИНО...» — дим. Тезәм инде шунда, болгатам. Сәхнәдән куып төшергәнче дип ашыгу. Шунда, Әхмәтсафакаем, ышансаң ышан, ышанмасаң юк — бөтен залга кычкырып әйтте Такташ: «Таныйм мин сине, кызый, исемдә...— ди, җанкисәккәем.— Менә бу шигырьне синең өчен укыйм»,— дип, «Пәри кызы» дигән шигырен укыды. Теге чакта ТИНО сәхнәсендә Гөлсемгә укыган шигырьне... Мин, бу якты дөньяда иң бәхетсез кеше, Такташның үземә багышлап шигырь укыган мәлдә нинди бәхет диңгезендә йөзгәнемне белсәң... Мәңге онытасым юк. Чума-чума йөздем, чумырып-чумырып эчтем бәхетне шул чакта. Шулкадәрле яшисем килде дөньяда, шулкадәрле көч алдым, кичәдән соң өч көн ач йөрдем, акча юк, таныш-белешләр дә юк җүнле-башлы. Курсларга килеп эләгеп кенә ач үлемнән котылып калдым. Үзем ач йөрим, үзем көлеп-елмаеп туймыйм. Мәхәббәттән исерү дигәннәре хак икән. Бәхет шулай була икән ул, Әхмәтсафа...

Егет, исе китеп, Заһидәнең якты хатирәләрен тыңлап тора иде. Заһидә бермәл шулай күктә йөзеп алды да шапылдап җиргә төште. Бераз кыланчыкланып, тавышына ясалма кырыслык чаткылары өстәп:

— Рабиганны шундый бәхет диңгезендә йөздер, егет булсаң,— диде.— Хәер, сине күргән саен үзен бәхетле тоя торгандыр ул кызый. Минем кебек күктәге торнага ышанып, кулдагы чыпчыкны ычкындырган тиле-миле түгел инде ул, алайса... Үзең чибәр, үзең акыллы. Монда да ни җитте кешеләрне җибәрмиләр, өмет бар синдә, сиңа ышаналар, егеткәем,— дип, Әхмәтсафаны кысып кочаклап алды. Кызның тыгыз күкрәкләрен тоюдан егетнең тәннәре чымырдап куйды, сизмәстән, арткарак тайпылды. Кыз аны кочагыннан ычкындыру турында уйламый да иде, көлеп сөйләнүен дәвам итте.— Йә инде, оялма! Беркем дә күрмәде кочаклавымны...— Аннан, кулларын җибәреп, яшьле күзләрен Әхмәтсафага текәде:

— Хуш, сабакташ, исән-имин бул, сак йөре,— дип, җавап та көтмәстән, йөгерә-атлый китеп барды.

Бу очрашу төштәгедәй тоелса да, Заһидәнең әйткәннәре артыгы белән расланды. Ике-өч айга дип килгән Әхмәтсафа Урта Азиядә ике елдан артык гомер кичерде. Заһидәнең киңәшләре дә ярап куйды тагын. Ул аларны һәрчак истә тотты.

* * *

Үргәнеч аны салкын йөз белән каршы алды. Язның соңгы ае, ихата саен бакча, агачларның шау чәчәктә чагы артта калган, алар җимешләнеп киләләр иде. Ул шәһәргә килеп төшкән көнне ком бураны котырды. Заһидәнең «Өермәгә килеп эләксәң...» дигән сүзләрен кат-кат исенә алды ул.

Партиянең өяз комитетында да аны төксе кыяфәт белән каршы алдылар. Табигатьнең кешегә тәэсир итүеме бу — һәркайда чытык йөзле, үтә җитди кешеләр генә очрады беренче мәлдә. Заһидә дөрес әйткән, килсәң, сөенүче юк, китсәң, елап калучы булмаячак.

Иң тәүдә кадрлар бүлеге башлыгы Ниязов хозурына керде. Тулы гәүдәле, каратут йөзле бүлек мөдире вәкарь кыяфәт белән җентекләп Әхмәтсафага Оренбур губкомыннан, Бохарадан биргән язуларны караштырды, ашыкмыйча гына тәмәке төтәтеп алган булды. Тәмәке суырган арада күзләрен кысып, сынап-сынап, каршысында утырган егеткә карап ала, төтенне исә нигәдер аска иелә төшеп, юан ботлары арасыннан коңгырт япмалы өстәл астына өрә. Табигый ки, төтен өстәл астына сыеша алмый, өскә бәреп чыга; өстәл, Ниязов үзе дүрт яклап күксел төтен камалышында калган сыман. Күрешкәндә үк бүлек мөдире үзен «уртак Ниязов» дип таныштырган иде. Уртак — үзбәкчә иптәш дигән сүз икән, Бохарада ишеткән иде инде — совет-фирка хезмәтендәгеләргә «юлдаш» дип тә эндәшәләр, казахчалап «җолдас» диючеләр дә бар. Үзбәкстан күп шивәле, күпмилләтле ил булып чыкты. Төшенеп өлгерде Әхмәтсафа — шушы Үргәнечтә генә дә үзбәк, казах, төрекмән, каракалпаклар яши. Кая барып чыксаң да, татарны очратасың, аларны җирле халык нугай дип йөртә, таҗиклар да аз түгел.

— Тагын бер нугай баласын эшкә өйрәтәсе икән...— дип сузды Ниязов, егетнең кәгазьләрен әйләндерүдән әллә арып, әллә туеп туктагач. Кесәсеннән бер бәйләм ачкыч чыгарып, ян-якта боегып утырган сейфны шалтыр-шолтыр китереп ачып җибәрде, өстә яткан калын гына кенәгәне тартып чыгарды һәм, һәр сүзенә бик зур мәгънә салгандай, күзен кыса төшеп, авыз эченнән сөйләнгәндәй, ләкин егеткә ачык ишетелерлек итеп, берничә кәлимә сүз ыргытты.— Монда сезнең якташлар аз имәс, анча-күп булдылар алар. Менә бу кенәгәгә һәркайсы теркәлеп куелган, иренмичә актарып чыксаң, кем-

нәр генә килеп, кемнәр генә китмәгән... Кем килеп чыкса да, кадрлар бүлеге аша үтә. Эшкә өйрәтеп кенә өлгер,— дип көрсенеп алган булды. Ниязов, авыр сулап, кемнәндер, нәрсәдәндер чирканган кыяфәт белән йөзен чыта төшеп, телефон трубкасына үрелде, кемгәдер Әхмәтсафа Дәүләтъяров исемле нугайның үзләренә эшкә җибәрелүен озаклап, тәфсилләп аңлатып маташты, аны ниндирәк эшкә тыгарга, ниндирәк урындыкка утырту хакында киңәште. Шушы сөйләшүдән соң да байтак вакыт тагын ниндидер кәгазьләр актаргалап утырды. Бүлек мөдиренең акрын кыймылдавының сәбәбе — аның шактый тулы гәүдәле, юан корсаклы булудан иде, ахры. Болай карап кына торудан Ниязовның нинди милләттән икәнлеген аерып әйтү кыен булса да, үз-үзенең дәрәҗәсен белүеннән аның шушы якларда туып-үскән, яки инде монда озак еллар яшәгән, мондагы хәл-әхвәлләрне биш бармагы сыман белүче кеше икәнлеге хакында сөйли иде. Тагын шунысына игътибар итте Әхмәтсафа: Ниязов үзбәкчә сүзләрнең кайберсен татарчалап та кабатлап куя, әйткән сүзләре егеткә аңлаешлы булсын өчен тырышкан кебек.

Ниязов янә телефонга үрелде, трубканы колагына куеп, кемгә, ни дип шылтыратырга тиешлеген онытып, җәфаланып утырган эшем ияседәй күзләрен кысып, бертын түшәмгә текәп торды, янә, авыр сулап, өстәл астына бүрек кадәрле аксыл төтен бөркеде, аннан салкын гына:

— Фиркалеме? — дип сорады.

Сорау урынсыз иде, егетнең юлламасына барысын да ачык итеп язып куйганнар лабаса. Шулай да Әхмәтсафа сорауга тыныч кына җавап кайтарды:

— Кандидат... Егерме дүртенче елның октябреннән,— диде. Шушы минутларда алдагы язмышы хәл ителгәнен тоеп, тынын кыса төште.

— Массалар арасында эшләгәнең бармы? — Әхмәтсафаның аптырабрак калуын күргәч, Ниязов сүзләренә ачыклык кертәсе итте.— Михнәткәшкә — хезмәт иясенә, кәмбәгал — ярлы халыкка, диһкан — игенчегә сәяси мәсьәләләр хакында аңлата алырсыңмы? Ил, мәркәз, өяздәге хәлләр белән таныштыруны йөкләсәк, тарта алырсыңмы? — Сорауны бирде дә җавап та көтмәстән әйтеп салды.— Сине агитация-пропаганда бүлегенә билгелибез. Әлегә вазифаң, агымдагы вазгыятькә карап, аерым йомышларны үтәү булыр, атап әйткәндә, инструктор йөген тартырсың. Үзеңне сәяси яктан ышанычлы, белемле, тырыш, уҗәт итеп күрсәтә алсаң, күтәрербез. Бездә нугайлар эш башына тиз менеп утыралар,— дип тә өстәде. Ниязов, иң ахырдан, дустанә елмаеп, Әхмәтсафага кулын сузды.— Мин дә Оренбур якларыннан. Ярым казах, ярым нугай булам. Ата-ананы, туган җирне, якташларны сайлап ал-

мыйлар, ничек бар — шулай инде,— дип, Әхмәтсафага бик үк аңлашылып җитмәгән фәлсәфә дә куертып алды.

Әхмәтсафа кебек «берничә айга» дип кенә җибәрелүче егет-кызлар өяздә унлап җыелды. Башта аларга элекке хәрби казармалардан — тулай торактан урын-җир бирделәр, аннан атна-ун көн нык кына эшкә өйрәттеләр. Шәһәр эчендә корал белән йөрү мәҗбүри түгел, әмма кышлакларга чыкканда, коралны алу лазем икән. Инкыйлабтан соң совет хакимияте өчен Үргәнеч, Хива якларында хәлләр артык кискен булмаса да (1920 елда төбәккә кызыл гаскәрләр килеп җитүгә үк, Хивада милли ихтиляльчылар тарафыннан ханлыкны бәреп төшереп, советлар төзелә. Үргәнечтә — Хивадан утыз биш-кырык чакрымдагы шәһәрдә дә — совет хакимияте җирле ихтиляльчылар ярдәмендә урнаштырылган), монда бик үк тыныч та дип әйтеп булмый. Шуларны истә тотып булса кирәк, хакимияткә эшкә җибәрелгән яшьләрне берничә көн корал тотарга, атта йөрергә, җирле халыкның гореф-гадәтләренә өйрәттеләр. Өйрәтүчеләр кызыл гаскәриләр иде, алар кат-кат искә төшереп тордылар: хәрби хәзерлек мәсьәләсенә игътибар итмәү аркасында, беренче нәүбәттә яңа килгән совет хезмәткәрләре күп кенә фаҗигале хәлләргә юлыкканнар. Алар да менә Әхмәтсафа, аның иштәшләре кебек, игелекле ният белән — җирле халыкны яңа, матур тормышка чыгарабыз дип җилкенеп килгән булганнар, тик үзбәкләр тарафыннан аларны «ләббәйкә» дип кабул итүче генә булмаган... «Ярдәм» итү нияте белән килүчеләрнең шактые ком чүлләрендә юкка чыккан. Нинди җил, өермә, сил йоткан аларны?.. Кем дә белми — чүлнең хәтере мәңгелек булса да, аның теле юк, ул эндәшми...

Урта Азиядә сәяси хәл чагыштырмача тотрыклана төшкәч, узган ел гына Олы Төркстанны кисәкләргә таркатырга керешкәннәр — ул Үзбәкстан, Төрекмәнстан, Таҗикстан кебек республикаларга бүлгәләнгән. Галәмәт зур мәйданнарны биләгән өлкә идарә итү өчен җыйнакланган. Хәзер инде урындагы хакимиятне белемле кадрлар белән тәэмин итү, халыкның хакимияткә ышанычын арттыру, халык белән хезмәттәшлекне ныгыту бурычы тора. Әхмәтсафа шушы эшләрнең үзәгендә кайнарга тиеш иде.

Үргәнеч үзе борынгы шәһәр, ике өлештән — Яңа кала һәм Иске каладан тора. Иске каладан дистә чакрымлап читтәрәк борынгы ханлык истәлеге — төрбәләр, мәчет, башка элгәрге корылмаларның җимерелгән калдыклары. Анда халык изге урынга йөргән кебек табынырга йөри. Яңа калада исә көндәлек тормыш ыгы-зыгысы. Халыкның ни-нәрсә белән мәшгуль булуын әйтеп бетереп булмый. Шәһәрдә мамык чистарту, мамык мае эшләп чыгара торган заводлар бар,

сабын кайнаталар (хәзерге чисталык фронтында бу иң әһәмиятле участок дип аңлаттылар), тегү фабрикасы эшли. Борынгылык һәркайда күзгә чалына. Урамнар тар, тыкрык-күчәләр шактый биек һәм шыксыз, әллә балчык, әллә комташтан өелгән дуван-коймалар белән әйләндереп алынган, алар эчендә нинди хәлләр бар — анысын бер Ходай гына белә. Һәр мәхәлләнең үз чалымы, үз тормышы. Нэп сәясәте нәтиҗәседер инде, базарлар тернәкләнеп килә, монысы да яңа хакимиятнең олы казанышы сыйфатында телгә алына. Базарсыз халык — беткән халык, базар бар, димәк, халык яши. Соңгы чорда халыкка җәдитче-ихтиляльчыларның йогынтысы зур булуын да искәрттеләр.

Җәдитчеләрнең ныклап сәяси мәйданга килүе Бохара белән бәйле. «Яшь бохарачылар», күп михнәтләр чигеп, Бохара әмиренә каршы көрәш җәелдергәннәр, кызыл гаскәрләр — татар-мөселман бригадалары булышлыгы белән, әлбәттә, әмирне куып, хакимиятне кулга алганнар. Аннан Рәсәй белән каршылыкка кереп, инглиз һәм чиктәш мөселман дәүләтләре белән элемтәдә, бер сүздә булып, хакимлеккә советларны үткәрмәү нияте белән, тагын көрәшкә күтәрелгәннәр. Аяусыз көрәш була бу. Куйбышев, Фрунзе, Кәрим Хәкимов кебек большевистик рухлы рәхимсез коммунистлар кулы белән җәдитчеләр җиңелә, Совет хакимияте ныгып кала. Бу көрәшләр Хива, Үргәнечне читләтеп үтмәсәләр дә, төп вакыйгалар Бохараның үзендә, кышлак-вилаятьләрдә булганлыктан, монда хәл шактый тотрыклы дип исәпләнелә, Әхмәтсафа шикелле бу төбәккә яңа килеп эшкә керешүчеләр, уяулыкны югалту аркасында, еш кына четерекле хәлләргә дә тарыйлар иде. Татар-нугайларга (алар монда шактый күпсанлы булып чыктылар), совет хакимияте урнаштырган чакта күрсәткән рәхимсезлекләре нисбәтле, җирле халыкның карашы, тышка бәреп чыкмаса да, эчкә яшеренгән үчлекле караш иде. Нугайга урыска сатылган, муенына тавык тәпие аскан нәмәкәй дип карау нык сизелә, туры килсә, үчне тышка чыгарудан да тайчанып тормый үзбәк халкы. Шуларны исәпкә алып, алны-артны чамалап йөрергә туры киләчәк иде.

Җирле халык белән аралашып, аларның уй-гамәлләрен өйрәнеп бетергәнче өч ай да үтеп китте. Инде көзгә керергә җыена табигать, җәйге каникул үтеп бара, Әхмәтсафа, документларын алып, кире Оренбурга, укуын дәвам итәргә кайтып китәргә дип килсә... егетнең гозерен тыңлап утырган Ниязовның керфеге дә селкенми. Ул янә өстәл астына төтен өреп, өзек-төтек рәвештә, хәзерге вазгыять хакында сафсата куерта башлады.

— Һәй, нугай баласы,— диде ул, үз итеп елмайган бу-

лып, әмма бу елмаю күбрәк мәсхәрәле, егетнең теләге белән бөтенләй санлашмый торган елмаю иде. — Киләп сарып йөрдем дә хәзер кайтып китәм дисеңме? Чынлапмы бу?.. Оялмыйча бармак башы кадәр эш күрсәтми кайтып китмәкче буласыңмы? Уйла, егет! Без сиңа өч ай дәвамында хезмәт хакы-айлык түләп тордык, ашханәдә тамак туклыгы иттердек, әнә чыраеңа бак — тазарып, матураеп, йомрыланып киттең, күз тимәсен... Корал тотарга өйрәттек, атка атланып кайларга гына йөрмәдең. — Әхмәтсафаның нидер әйтергә теләвен сизеп, кулын күтәреп, егетнең дәшми торуын үтенгән хәрәкәт ясады. — Беләм, беләм, нугай баласы, әйбәт эшләвеңне дә беләм, кайда барсаң да кәмбәгалга гүзәл гәптәш булдың, массаларга сәясәтне дөрес ирештердең, телгә алырлык хаталарың булмады, абруең бар өяз комитетында. Синең кебек кадрларны югалту кыен. Сине Хивага, округ комитетына сорап запрос килде. Яшермим, тартышып карадым, ләкин фиркагә, мәркәзгә мин каршы килә алмыйм. Документларың Хивада, анда кирәк син, сине анда көтәләр юлдашлар. — Ниязов, урыныннан кузгалып, егет янына килде, итләч кулын егетнең сөякчел иңсәсенә салып, үгетләп-юмалап сүзен дәвам итте. — Укуың бүгенге вазгыять өчен җитеп ашкан, Дәүләтъяров. Ничек диләр әле, укып мулла булмассың, чукып карга булмассың, диләрме? Нугайлар төртмә телле халык, ничек әйтергә беләләр, һех-һех. — Ниязов көчәнеп көлеп алды. — Син дә ташлап кит, башкалар да китсен, монда яңа тормышны кем төзер? Валлаһи, чүлдә янтак-үлән эзләп таралган куй сыман, таю ягын гына карый хәзерге яшьләр. Булачак көрәшчеләр, имеш... Кем монда хакимиятне ныгытыр? Үзбәк халкы советны кайчан үз итәр, кайчан аңа йөз белән борылыр? Уйлап караганың бармы?

Әхмәтсафа эндәшмәде. Ниязовның үгетләве кирәк түгел аңа, төбәктәге халыкның совет хөкүмәтенә карашын яхшы белә. Монда аңа да, башкаларга да эш җитәрлек. Ул өч ай түгел, өч ел эшләргә дә риза. Тик... аны Оренбурда Рабигасы көтә. Ул бит, өч айдан кайтам, дип, сүз биреп китте. Вәгъдә — иман... Кызый әлеге сөйләшүне ишетсә, ни дияр иде икән? Ни хәл итәргә?

Ниязов исә үзенекен тукый:

— Документларыңны карап чыктым. Кандидатлык вакытың үтеп бара. Фиркагә Хивада, округ комитетында керсәң, һич тә зыян итмәс. Әле синең яшисе бар, совет хезмәтендә чарлана-чарлана үсәсең бар. Чын совет хезмәткәре булып җитешеп кенә килгәндә, «каникул бетте» дип, тот та китеп бар. Акылга сыймый. Фирка эшендә каникул юк, егет! Башланган эш — беткән эш, иелгән башны кылыч кисми, карышма, кал әле Хивада. Үзең үк рәхмәт әйтерсең. Бераз вакыт

үтсен. Акча ягың да рәтләнер, өстең бөтәер. Егет кешегә кирәк ул. Ниязов юк-бар сүз такылдап утыручы түгел, минем сүзләр әле исеңә төшәр!..— дип, бүлек мөдире өстәл өстеннән алдан ук әзерләп куйган юлламаны алып, Әхмәтсафага сузды.

Икенче көнне Әхмәтсафа Хивага килеп төште...

* * *

— Аңлыйм, аңлыйм,— диде округ партия комитетының оештыру бүлеге мөдире Рәҗәпов каршысында утырган Әхмәтсафаның, һичшиксез, Оренбурга кайтып, укуын тәмамларга кирәклеге хакында кайнарланып сөйләвен тыңлаганнан соң.— Миннән генә торса, ике куллап җибәрер идем, уртак Дәүләтъяров. Калган эшкә кар ява, диләр нугайлар. Дөрес сүзләрең, бик дөрес әйтәсең...— Ул, кесәсеннән тәмәке чыгарып, Әхмәтсафага сузды.— Күп сүз бозау имезә, ди, берне көйрәтеп җибәрик.

— Рәхмәт, тартмыйм,— диде Әхмәтсафа үртәлеп.— Үзегез кадрлар белән яңача эшләү кирәклеге хакында гәпәрдегез, үзегез кешеләрне төрлечә алдап эшкә калдырмакчы. Дөрес юл димәс идем, уртак Рәҗәпов.

Рәҗәпов көлеп җибәрде. Тәмәкесенә ут элдереп тәрәзә янына килеп басты һәм, нәкъ Ниязов шикелле башын чөңкәйтеп, тәмәкесен тирән итеп суырды да төтенен тәрәз пәрдәсе артына өреп җибәрде. Тәрәзә өлгеләренә сыеша алмый зәһәрләнеп-дулап, зәңгәр төтен чабыша башлады.

— Син инде ничә мәртәбә алдау, алдашу дигән сүз ычкындырдың. Яңадан әйтмә бу сүзеңне. Фиркадәшләрчә түгеллеген искәртәм, шул гына. Монда инкыйлабны, асылда, нугай-татарлардан торган мөселман батальоннары ясады. Җәдитче яшь көчләр, нугайлар килеп җиткәнче үк, Хивада, Бохарада хакимиятне үз кулларына алырга теләп, кузгалыш оештырдылар оештыруын, тик уңышка Хивада гына ирештеләр. Ул чакта мин дә җәдитчеләр сафында идем. Бохарада түгелгән кан дәрья булгандыр. Катлаулы чор иде. Хивада хакимлекне алдык, аны бит тотып торырга көч — белем кирәк. Монысын да булдырыр идек тыштан тыкшыну булмаса. Бер яктан — Рәсәй, икенче яктан — башка илләр... Кайсыдыр якка авышырга кирәк иде, шунсыз котылу юк. Без Рәсәйне сайладык. Ул дәверне сөйләп китсәң... Күрде бу яклар. Аксак Тимердән соң инкыйлабка кадәр моның ише хикмәтләр булмагандыр. Зәки Вәлиди дә үтте моннан үзенең үгет-нәсихәтләре белән. Әнвәр паша килеп, яу оештырып йөрде. Үзебезнең Фәйзуллаев, Ходжаевлар да шактый эш майтарып ташладылар. Мирсәет Солтангалиевнең бергә-

лек идеясе якын иде күңелгә. Әмма... әмма... Мәскәү төркиләрнең берләшүгә омтылышын җиңел генә хәл итте дә куйды. Олы Төркстанны бүлгәләп-таратып бетерде. Безнең Хива республикасы җирләре хәзер Үзбәкстан, Төрекмәнстан, Каракалпак дәүләтләре эчендә. Бүлгәлә һәм хакимлек ит!.. Сәясәт аңлашыла торгандыр. Ә син алдашу дисең...

Рәҗәпов янә өстәл артына килеп утырды. Әхмәтсафа әлеге сәяси агартуның үзе өчен үткәрелүен яхшы аңласа да, Рәҗәповның тел төбен аңлап җиткерми иде әле. Моны Рәҗәпов үзе дә сизенде булса кирәк, сүзен дәвам итте.

— Мирсәет әкәнең башын ашадылар. Минем Мәскәүдә рабфакта укып йөргән чак, ул хәлләрне яхшы беләм. Күргәнеңчә, мине дә Мәскәүдә озак тотмадылар. «Үзбәкстанга җирле кадрлар кирәк» дип кайтарып җибәрделәр. Кадрлар җитми, кадрлар,— диде ул ачынып.— Мәскәүдә укыган елларда минем карашлар да шактый үзгәреш кичерде, Рәсәйгә үчләшеп, әллә ни майтарып булмаячак. Шушы вазгыятьне үзбәк халкына мөмкин кадәр отышлырак итеп файдаланып калу кирәк. Безнең башка чара юк әлегә... Әүвәлге елларда бөгелешләр күпкәрәк киткән. Җәдитчеләр, кемнең кем булуына карамастан, өерләре белән фиркагә кергәннәр, коммунист булганнар. Аларның күпчелеге Солтангалиев идеяләре белән сугарылган иде һәм бу омтылыш фирка тарафыннан яклау да тапкан иде. Хәзер исә киресенчә, кем Мирсәет әкәнең идеясенәябышып ята, андыйларны Мәскәү күрсәтмәсе буенча өерләре белән фиркадән чыгарып аттык. Мин, әйткәнемчә, Мирсәет әкәне ихтирам итәм, әмма фирка линиясе тармаклы була алмый. Фиркадән чыгарылганнарның күбесе үзләрен үзбәк ихтиляльнең әттәләре дип санаучылар иде, биләгән урыннарын югалтуны авыр кичерделәр. Тартышу озаккарак китте шул. Эшкә аяк чалулары бер хәл, аларның халык алдында абруйлары бар, аларга ышана халык, безгә түгел. Тез астына иң нык сукканы — кешеләр җитми, уртак Дәүләтъяров, кешеләр кирәк. Яныңда ышанычлы кешеләр булмаса, бер эшне дә башкарып чыга алмыйсың. Хива, Бохара кадрлар белән ярыйсы гына тәэмин ителгән анысы. Кешеләрне шәһәрдә калдыру җиңелрәк, шәһәр һавасы барыбер үзен сиздерә. Бер якта — Караком, икенче якта Кызылком сахралары булса да, тимер юл якын, дарья, шөкер, кул сузымы гына. Ә эчкәре вилаятьләргә кем барыр? Анда эшне кем белән, ничек оештырырга? Хакимлекне ничек кулда тотарга? Властьны кулдан ычкындырсаң — беттең, тагын кан коеш, суеш башланачак. Бу нәп дигәннәре, ярый, сәүдәгә иркенлек биреп, диһканнар күзләрен бераз ачты әлегә, артык мамыкларын сата алалар. Базар да тернәкләнеп килә. Тик сәүдә тирәсендә болганган халык — иң ышанычсыз

халык ул. Бүген болайга борыла, иртәгә тегеләйгә. Сатуга күнеккән кеше акча керемен генә уйлый. Әҗере тиярдәй булса, барысын да сата. Хәтта хатынын да. Кызын сатып җибәрергә әзер. Шундый хәлләр... Менә шушы халыкны мең ел дәвамында чарланган гадәтләреннән аерып кара син!.. Кадрларны табып алабыз алуын, эшкә дә өйрәтәбез, инде кул арасына кирәклек кеше булды дигәндә, мәркәздән директива килеп төшә. Үзбәкстанның башка өлкәләре — Наманган, Сәмәрканд, Фирганә якларына кешеләр сорыйлар, таләп итәләр, тыңламасаң, яныйлар. Җибәрми нишлисең? Шәп егетләрне кулдан ычкындырдык, шунсы жәл. Сез нугайларда өмет, уртак Дәүләтъяров, сезгә өмет баглыйбыз. Әмирлекне пыр туздырып, хакимлекне алып бирдегез, инде кулда тотарга булышыгыз. Башка чара юк. Синең кебек урысча белгән егет урамда аунап ятмый. Фиркагә алырбыз, кандидатлык вакыты үткәнен көтеп тормабыз. Нәкъ шундый егет кирәк безгә. Миндә уртак Ниязов язган холыкнамәң бар. Яхшы яктан күрсәтә. Эшлик, фирка шигарендә әйтелгәнчә, чүлдән гөлбакча ясыйк!

Әхмәтсафа Рәҗәповны тыңлый да, тыңламый да кебек. Ул бит әле август башында гына Рабигага хат язып җибәргән иде. «Озакламый кайтып җитәм, көт»,— диде... Ул хат, һичшиксез, инде Рабигасы, төшләренә кереп йөдәтүче сөйкемлесе кулына эләккәндер, чөнки Рабига аны вокзалга озата төшкәч, бу җәйгә корган ниятләре белән уртаклашкан иде. «Атбасарга — туган шәһәремә кайтып киләм дә анда озак юанмам, җәйге каникулда Оренбурдагы берәр балалар йортына тәрбияче булып урнашырмын, аз булса да акча, яшәргә мая булыр»,— дип сөйләнгән иде. Кыз күптән Оренбурда инде, аның кайтуын көтә торгандыр...

Рабига бертын эчендә күңел капчыгын бушатып бетерүчеләрдән түгел. Танышып инде егеткә ияләшкәннән соң, бер кичне урамга йөрергә чыккач, бераз чишелеп, үзенең тормыш хәлләрен дә сөйләштереп алган иде. Әхмәтсафаның белгән кадәресе шул: Атбасарда яшәүче әтисе, Мөхәммәтҗан исемле үзбәк — диндар, кадими кеше, кызларының (әле аның Бибиҗамал исемле апасы да бар икән) яңача яшәүгә омтылуларын һич тә хупламый, шуның өчен әнисен — татар хатыны Хәлимә апаны бик тә рәнҗетә, кечкенә ике улын ияртеп, куып җибәрү белән яный, кыскасы, кызлары үчен анасыннан ала, шуны бик авыр кичерә иде Рабига. Атасының яшь хатыны да бар икән, ике дә уйламый куып чыгарыр әнине дип, тәмам аптыраашта да калгалый иде ул. Инде үзе дә укуын өзеп кайтып китә алмый, әтисе — үзбәк карты тәртипләренә күнә алмаячак ул, мәңге түзеп тормаячак. Әнисе кызганыч, шул үзәкне өзә. Куып чыгарса, әни энеләрем бе-

лән кая барыр, кемгә сыеныр дип өзгәләнгәч, сөеклесен бермәлне Әхмәтсафа юатып та маташты:

— Кайгырма, Рабига, укып кына бетерик, барысы да җайланыр. Әниеңне — Хәлимә апайны да йолып алырбыз.

— Кемнән? — дип гаҗәпләнеп сорады Рабига.

— Әтиеңнән! — диде егет, инде барысы да хәл ителгән кебек.— Кыерсыта икән, моңа һаман да юл куярга ярамый.

Кыз күз яшьләрен сөртеп, елмайгандай итте:

— Әй, Әхмәтсафа, Әхмәтсафа... Кайсы хатын-кызның гомер иткән иреннән язып, ялгыз каласы килсен. Гаиләдә өйне тотучы хатын-кыз булса да, туйдыручы ир кеше бит. Минем әнием тегү-чигү эшенә оста, өй эшләренә бик һәвәс, йомшак күңелле, басынкы кеше. Әти исә ямчы, гомер буе юлда, диндар, каты куллы карт, өйдә аның сүзе генә сүз. Гомер бакый шундый тәртип булуын теләде. Башта Җамал апа чыкты әти сүзеннән. Ул өяздә хатын-кыз хәрәкәтен оештыручыларның иң тәүгесе иде. Аннан мең бәла белән мине озатты апам укырга. Әти ризалыгыннан башка. Әни, бичара, ул чакта әтинең талавына ничек түзгәндер... Әле бит энеләр дә бар. Гадәт буенча апам белән мине тугач ук әти үзенең ямчы дусаркадашларының улларына ярәшеп куйган. Шулай итеп, без инде ярәшелгән кызлар, колаклар тешләнгән,— дип, хәсрәтле көлеп алган иде Рабига.

— Ярәшелгән дип...— Әхмәтсафа кызны кирегә үгетләгәндәй, сөйләнеп алды.— Ул бит инде искелек кәсафәте. Моңа хәзер кем ышансын?..

— Безнең әти кадими кеше,— диде Рабига, бу юлы тагын да җитдирәк иде тавышы.— Сүзеннән чыккан өчен безне кичерә алмый. «Ил-көн алдына чыгарлыгым калмады, кызларымны марҗа иттең»,— дип, әнигә көн-төн бәйләнә, җәберли. И-и, түзсә дә түзә икән золымга татар хатыны...

Рабига, башын түбән иеп, тын гына атлый бирде. Бу сөйләшү Әхмәтсафа Бохарага китәр алдыннан булган иде. Соңгы хатында егет Рабигасын тынычландырырга тырышып, «әгәр әниең Оренбурга, синең янга килеп урнашырга теләсә, мин китәр алдыннан Гомәр абый белән сөйләшкән идем, һич аптырамасыннар, Хәлимә апай белән энекәшләрең бездә торыр. Алда ничек яшәрбез, тормыш ничек булыр, анысын мин кайтып, укулар тәмамлангач, карарбыз...» дип тә өстәгән иде.

Бәлки, язылганнарның төп асылын Рабига төшенеп тә җитмәс, ләкин егет инде үзе чамалый, аның күңеленә бу дөньяда Рабигадан башка беркем дә якын түгел; шушы җыйнак кына гәүдәле, ягымлы карашлы, тыйнак кыз җанына кереп утырды да, кузгалып та карамый, егетне иләсләндереп тик йөри. Төшкә керми калган төне юк, кайту көннәре якынлашкан

саен, сагыну-юксыну хисләре отыры көчәя бара иде, менә сиңа мә, дөя урынына ишәк дигәндәй, үзбәк дуслар аны кайтарып җибәрү турында уйлап та карамыйлар. «Килгәнсең икән, яңа тормыш төзеп бетермичә китү юк!» — дип, авыз ерып тик торалар. Аңа кеше итеп карау юк, үз сүзеңне тәкрарларга маташсаң, фирка исеме белән авызыңны томалап кына куялар. Капты егет капкынга, фирка муеныннан эләктереп алган да җибәрми генә бит, кана. Каршы килсәң, укыган җиреңә, губерна комитетына холыкнамә җибәрәбез, дип шүрләтәләр. Егетнең яхшы якларын санап, күрсәткән игелекләрен язып түгел инде. Гомеренең тәүге эш елларында ук начар холыкнамә җыясы килми, әлбәттә. Фиркагә кергәндә: «Яңа тормыш төзүчеләрнең иң алгы сафында буласым килә, фирка өчен гомерем дә жәл түгел!» — дип, каткат әйттерделәр аннан өлкән иптәшләр. Яңа тормыш төзүдә катнашасы җирнең адресы күрсәтелмәгән иде. Ул җир Үзбәкстанда булып чыкты менә, әлегә аннан гомерен бирүне таләп иткән кеше юк. Җанында каршылыклы уйлар кайнашса да, риза булды, тагын бер елга калырга килеште.

Рәҗәпов, егетнең йөзендәге чарасызлык чаткыларын күрмәмешкә салышып, аңа йомшак кулын сузды.

— Менә бу егетләрчә! Нугай егете сынатмас дигән идем, дөрес уйлаганмын. Аннан бая Әхмәтсафаның «тәмәке тартмыйм» дигән сүзләре исенә төшепме, аңа дустанә тавыш белән киңәш бирәсе итте. — Тартмыйча дөрес эшләмисең, иптәш Дәүләтъяров! Егет кеше икәнсең, тәмәке тарт, һич тә булмаса насбай булсын авызыңда. Борын астында мыек та булу шарт. Шунсыз үзбәкләр сине егет кешегә, ир-ат халкына санамас. Тәмәке тартмаган, әфьюн, насбай кулланмаган, сакал-мыексыз егетләрне хатын-кыз урынына кулланалар монда, белеп тор. Монда тәртип шулай.

Әхмәтсафа әлеге ятышсыз сүзләргә каршы ни әйтергә белми тора иде, Рәҗәпов үзе ачыклык кертте:

— Элек ханнар, байлар хатыннары өстенә уйнаш өчен гарем — кызлар белән бергә ак тәнле малайларны да тота торган булганнар. Кызлар кебек үк файдаланганнар малайларны. Бу якта киң таралган нәрсә ул. Шуңа күрә йөзеңә карау белән синең ир-ат халкы булуыңны аңлап алсыннар. Абруйга шик-мазар төшәрлек булмасын... Аңлагансыңдыр?

Әхмәтсафа, Рәҗәповны җирәнеп тыңласа да, аның сүзләре тәэсирле булды, шул ук көнне инде кесәсендә папирос, шырпы пәйда булды. Ай үтмәгәндер, округ комитетының статистика-хәбәр бүлеге мөдиренең борын астында җыйнак кына мыек та үсеп чыкты. Инде хәзер һәрьяктан ярарлык булды: фиркагә дә каршы төшмәде, абруйга да зыян килерлек түгел иде. Үзенең тиз генә әйләнеп кайта алмавы хакын-

да Рабигага язып җибәргән иде, озак та үтмәде, кыздан хат килеп төште. Кыз Әхмәтсафаның хәленә керергә тырышып язган иде, борчылмаска кушкан, көтәм, дип вәгъдә дә биреп куйган. Егетнең кәефе күтәрелде, үзе килгәнче бөтенләй таркалып бетә язган бүлектә эшне тәртипкә салу нияте белән җиң сызганып вазифага кереште.

* * *

Эшенә дә, кешеләренә дә ияләшеп килгәндә генә, Әхмәтсафага яңа хезмәт урыны тәкъдим иттеләр. Хорезм округ комитетының җаваплы инструкторы итеп билгеләнде ул.

Эш белән онытылып, көннәрнең бер-бер артлы йотыла баруын да тоймый калды, инде 1926 елның җәе дә үтеп бара икән. Шактый бертөрлегә әйләнеп беткән көннәрен җанландырган бер вакыйганы искә ала да Әхмәтсафа шаклар ката. Бу дөнья бер карасаң, шулкадәрле киң, зур сыман. Шушы Хива якларын гына ал. Һәр ике якта диңгез сыман ком сахрасы җәйрәп ята. Чүл барысын да йотып кына барган кебек. Аерым бер кешегә ни сан — сәфәргә кузгалган зур-зур кәрваннар да кибәнгә төшкән инә сыман гына монда. Бер офыкка кереп күмелгәч, кемнең кайда йөргәнен дә белмәле түгел. Атналар буе хәбәр көтәсең, эзсез-нисез юкка чыккан кебек алар. Мәңге табарлык түгел сыман. Айлар үтә, шулай да бер җай табып, исәнлекләрен белдереп куялар тагын. Чүл чүл инде, аңлашыла да. Хәтәр юл, хәвефле як. Әхмәтсафа шуны уйлый да үзе яшәгән Оренбур якларын искә төшерә — күрше авылда гына яшәп яткан яхшы танышыңны, яисә якын туганыңны дистә еллар күрми яшисең. Кайберсе белән элемтә бөтенләй өзелеп, кайда гомер сөргәнен дә оныта башлыйсың. Әхмәтсафа да Саттарның эзен югалтты менә. Аның белән Бохарада аерылышкан иде, Рабиганың хатлары буенча дустының шактый дәрәҗәле хезмәт башкаруын белә һәм шуның белән вәссәлам. Күрешкәне, очрашканы юк. Хивада елдан артык яшәп, ныклап танышып, дуслашып киткән кешесе дә юк. Монда барысы да үзләрен вакытлыча килгән кешегә генә саныйлар. Кайсы көзгә чаклы дип гомер үткәрә, кемдер ел башыннан каядыр китмәкче. Һәркем моннан тизрәк китү уе белән яна. Сүз сөрешләрендә мантыйк юк түгел — биредә шактый җаваплы урыннарны биләгән кешегә Урал, Идел буйларына кайтып төшсәләр, һичшиксез, игътибар итми калмаслар дип ышаналар. Утны-суны кичеп кайткан фирка солдатлары бит алар. Бәлки, кемдер Мәскәү тирәсендә дә эш таба алыр. Һәрвакыт ишетеп торалар ич, кадрларны чәчеп үстермиләр. Менә шушындый җәһәннәм түрләрендә җитешә дә инде иң кыйм-

мәтле кадрлар! Вакытында күреп алулары гына кирәк, өстәгеләр сиңа игътибар иткәнче үк үзеңне күрсәтеп өлгерсәң, бигрәк тә яхшы. Кыек-мыек сөйләп торасы юк, Әхмәтсафага очраган килмешәк түрәчекләрнең күбесе үзләрен кыйммәтле, белдекле кадрларга саныйлар, шуңа чын күңелдән ышаналар, башкаларның да үзләре хакында шулай уйлауларын телиләр иде. Күп кенә яшь хезмәткәрләр, Урта Азия республикаларына килеп эләгеп, артык көч, тир түкмичә һәм, дөресен әйтик, белем дәрәҗәсен исәпкә алып та тормастан, тиз генә шактый дәрәҗәле урыннар биләп алдылар. Моны алар, алдан әйтеп киткәнчә, очраклык, язмыш бүләге дип түгел, бәлки, үзләренең эшкә сәләтле, гайрәтле булулары белән аңлатырга азапланалар иде. Шул рәвешле, фирканең «җылы кулы» белән, дәрәҗә яраткан, әмма чын эшкә килгәндә шактый булдыксыз һәм надан яңа совет бюрократиясе туды. Мондый түрәләр янына белемле, эшне алып барырлык «йөк атлары» яки үзләре, эчтән көлеп, мыскыл итеп атаганча «совет ишәкләре» кирәк иде. Ниязов, Рәҗәпов кебекләр уенча, Әхмәтсафа Дәүләтъяров та шундый «ишәк»ләрнең берсенә әверелергә тиешле егет иде.

Шундый хәлләр... Илһамланып, янып-пешеп эшләп йөргәндә, көтмәгәндә округ комитеты урнашкан ике катлы бина алдында Фәтхулланы очратты Әхмәтсафа. Хәер, ул аңа игътибар да итмичә үтеп бара иде. Бу көнне педагогия техникумының яңа уку елына хәзерлеген тикшереп матавыкланды. Кәефе шәптән түгел иде. Алдагы көнне үк техникумга киләсен хәбәр иттереп куйса да, анда аяк атлап кергәч, ни мөдирнең, ни мөгаллимнәрнең берсенең дә эш урынында булмавын күреп, тәмам ярсып чыккан иде. Анысы бер хәл, әгәр эшеңне шәп башкарасың икән, окружкомнан түгел, әллә каян килгән вәкилне дә санга сукма ди, монда бит икенче мәсьәлә — бина эче ташландык бер корылманы хәтерләтә иде, җәй буена адәм аягы басмаган монда. Бүген-иртәгә уку елы башлана дип йөр син менә. Техникумның яңа уку елына хәзер булмавына җаны кыйналып, җилләнеп кайтып килгәндә, кемдер, артыннан куып җитеп, җиңеннән тартып туктатты:

— Уртак... Әхмәтсафа, син түгелме соң, авызыңа төкерим?!

Әхмәтсафа, барган җирдән кисәк туктап, аптырау катыш куанулы тавыш иясенә борылды. Каршысында милиция киемле, зур гәүдәле, төскә чибәр генә кеше басып тора иде. Һәм ул, егеттән ниндидер күңеленә ятыш сүз ишетергә теләгәндәй, балкып-елмаеп читкәрәк тартылды — мә, күр янәсе, таныйсыңмы абзаңны! Әхмәтсафа һушын җыеп өлгергән иде инде, каршысындагы бу бик тә мөлаем милиция вәкилен төсмерләп, танып та алды. Үзе дә сизмәстән:

— Фәтхулла абзый! — дип, теге кешенең кочагына ташланды.

Әлеге очрашудан Фәтхулла телгә килә алмыйча азапланды. Егетне кысып кочаклап алды да бертын җибәрми торды, аннан гына өтә-төтә сөйләшә башлады:

— Карыйм, бер чибәр егет килеп ята. Башка күсәк белән ордылар диярсең, Әхмәтсафа бит бу, мин әйтәм, авызыңа төкерим. Үзгәргәнсең болай, нәчәлник кыяфәте кергән, шулай да таныдым...

Әхмәтсафаның авыз ачуын көтмәстән, күңеленә килгән беренче сорауны бирергә ашыкты:

— Нишләп йөрисең монда?

— Тире җыеп, күн эшлим, — дип шаяртып җавап кайтарды Әхмәтсафа.

— Һи-и, Каеш, монда нинди тире булсын, чүл бүреләренең тиресен генә җыймасаң... — дип, шаяртуны эләктереп алды Фәтхулла.

Әхмәтсафа, артык озакка сузмыйча, үзенең инде елдан артык бу якларда эшләп йөрүен сөйләп биргәннән соң, Фәтхуллага сораулар яудырырга кереште:

— Син... Фәтхулла абзый, ничек әле монда? Милиция дисәм... Кайда эшлисең димме соң? Кайчан килдең Хивага? — Егет Каргалыда ук Фәтхулланың бу якларга чыгып китәргә җыенганын абзыйның үз авызыннан ишеткән иде. — Менә сиңа нинди очрашу! — дигән булды.

Алар шулай ишек катында шаулашып-гөрләшеп торалар иде, кемдер, үтеп барышлый, шелтәләгәндәй итеп:

— Юлдашлар, болай тору яхшы имәс, кешегә үтеп китәргә юл юк, читкәрәк китеп гәпәрегез, — диде.

Әхмәтсафа, исенә килеп, Фәтхулланы үзенең бүлмәсенә алып кереп китте. Бәхеткә, бүлмәдәшләре инде төшке ашка таралып беткәннәр иде, Әхмәтсафа зур калай чәйнек тотып чыгып китте дә тиз генә әйләнеп тә керде:

— Шунысы әйбәт, кизү бүлмәсендә һәрвакыт кайнар су була, ашыкканда йөгертеп кенә алып киләбез дә, бер чәйнек шаулап торган суга яшел чәй салып, эч күпкәнче эчәбез, — дип көлә-көлә, калай кружкага чәй агызып, Фәтхуллага сузды. Ул инде хуҗа кыяфәтенә кереп алган иде, кунагы алдына хәлвә, аз-маз тәм-том китереп куйды. Егетнең бар байлыгы шул иде. Үзе, Фәтхулланың каршысына утырып, бер йотым чәй уртлап куйды, мин сөйләдем, инде чират сиңа дигәндәй, сораулы-сынаулы карашын Фәтхуллага текәде.

Моны Фәтхулла да сизде. Нигәдер кашын җыерып, кружкасын өстәл уртасына таба этәрде һәм тавышын баса төшеп:

— Аптырадыңмы? — дип сорады.

— Ни дип әйтим... Киемең генә...

— Ат карагы милиция булгач, аптырасаң да сүз юк,— дип көлемсерәде Фәтхулла.

— Мин анысын әйтмим лә.— Ләкин Әхмәтсафа нәкъ шул турыда уйлап алган иде, шулай да аны авылдашына сиздермәскә тырышты.— Бу дөньяда кем башыннан ни узмас. Язмыш бәндә башыннан йөри, агач башыннан түгел.

Егетнең күпне кичергән өлкәннәр кебек сөйләшүе Фәтхулланың күңеленә хуш килде бугай, ачылып китте.

— Шулай, туганкай... Менә Хивага килеп төштем. Монда күптәнге танышлар, авылдашлар шактый иде минем. Тик дөньялар үзгәреп киткән, кирәкле дигәннәрен инде таба да алмадым. Эшкә урнашырга кирәк, хәтерлисең булыр, теге чакта ат урлау турында авыз сулары корытып сөйләсәм дә, мин ул эшне кәсеп үк итеп бетерә алмадым. Сезгә юлыккан төндә мин арадашчы гына булдым, кемнәрдер китерделәр, мин авылдан өч-дүрт чакрым ераклыкта каршы алдым, атны абзарга кертеп җибәрдем һәм... ул атның кайда китүенен дә, кемнәр алып киткәнен дә белмәдем. Сөйләшү шулай иде. Сез аптырадыгыз инде, әйеме, кая аткарды микән бахбайны дип. Миңа нәрсә, китәргә акча кирәк иде, нигәдер Каргалыга кайткач, күңелем ятмады авылга. Шәмсия апаң да гел китү ягын каерды. Хәзер сагынам дип елый. Хатын-кыз шулай икән ул, энекәш. Баш әйләндерергә маһир алар, авызларына төкерим.

— Шәмсия апай? — дип, кабат кайтарып сорады Әхмәтсафа.

— Минем белән инде. Ал тәгәрмәч кай тарафка тәгәри, арткысы да шунда иярә. Ачка үлеп булмый, киттем эш эзләп. Бер танышым ОГПУда эшли икән, аңа тап булдым, ул инде тезгенне шундук үз кулына алды. Гражданнар сугышында ниләр генә күрмәдек аның белән бергә, баштан ниләр генә кичермәдек, әмма бер-беребезне ташламадык ул чорда. Шушы иптәшем, авызына төкерим, мине милициягә китереп кертте. Башта курслар үттем, хәзер җинаятьчеләрне эзләү бүлегендә.

— Алайса, эш җитәрлектер инде?

— Дөресен әйткәндә, башка калалар белән чагыштырганда, тфү-тфү, әйтмәгәнем булсын, тынычлык әлегә шәһәрдә. Электән эшләүчеләрнең әйтүләренә караганда, күп кан коелган бу җирдә. Кан-яшь түгеп төзелгән хөкүмәт... Хәзер инде халык ризалашкан кебек язмышына. Тотрыклы тормышта җинаятьчелек тә кими дип өйрәттеләр безне. Әгәренки дәүләттә тәртип юк икән, югарыдагылар үзләре шухыр-мухырга һәвәс дигән сүз. Моны борынгы дәвердә яшәгән бер гыйлем иясе әйтеп калдырган. Шулай да шәһәрдән читтә, кышлак-вилаятьләрдә хәлләр четерекле. Әле яңа хөкүмәтнең буыны сыек, ныгып бетә алмый.

— Уку бушка китмәгән синең, Фәтхулла абый.

Фәтхулла егетнең шаяртуына игътибар итмәстән сөйләвен белде.

— Яңа икътисади сәясәт нәтиҗәсендә халыкка кот кунды, базар тернәкләнеп килә. Базар тирәсендә шпана, вактөяк караклык җитәрлек инде. Эш арта, күп вакытны шулар белән куышып үткәрәбез.— Фәтхулла, ашыгыч бер эше исенә төшкәндәй, кинәт урыныннан кубарылды.— Син кайда яшисең? — диде ул, башына йолдызлы кәпәчен киеп. Әхмәтсафа каршысында гаярь кыяфәтле хәрби киемле кеше пәйда булды кебек. Соравы да кырыс яңгырады.

— Тулай торакта ауныйбыз. «Совет хезмәткәрләре йорты»нда.

— Кит инде,— дип сузды Фәтхулла, карашында чагылган кырыслыгы, кул белән юып алгандай, юкка чыгарга да өлгерде.— Әйдә безгә, Шәмсия апаң белән дә күрешерсең. Сагынуы басылыр үз малаен күргәч,— дип дустанә елмайды.— Сезне телдән дә төшерми, үз балалары сыман сагына. Ул Бибкәйне инде әйткән дә юк. Гел бергә иделәр авылда. Киткән чакта көч-хәл белән аерылыштылар, картлар әйтмешли, йон-май түктеләр. Үзебез белән алып китик дигән идем, Гомәрхан каршы төште. Миңа бер йорттан өч бүлмә бирделәр, шактый зур йорт ул, берничә милиция хезмәткәре гаиләсе белән яши. Безгә шулай кулайрак. Ни дисәң дә, беребез өйдә булмасак, икенчебез өйдә була. Корал бар, андый-мондый хәл булса, дим. Дөньяңны онытып йөри торган җир түгел, ни булмас дисең…

— Миңа да револьвер бирделәр.— Әхмәтсафа өстәл астыннан корал тартып чыгарды.

— Корал бирүләре әйбәт анысы. Тик нишләп анда ята соң ул?

— Ә мин аның белән нишлим? Халык арасына чыкканда корал алып булмый. Безнең төп коралыбыз — сүз.

— Ай-һай, егеткәй, корал биргәннәр икән, юкка түгел инде бу, авызыңа төкерим…—дип шелтәләгәндәй итте Фәтхулла.— Бүген тыныч булыр, иртәгә әллә нинди хикмәтләргә юлыгырсың.

Әхмәтсафа револьверны тиз генә кире өстәл тартмасына салып куйды. Уйламаганда, көтмәгәндә мактанып ала торган гадәте бар инде аның. Шушы гадәте өчен ул үзен битәрләп бетерә алмый. Менә хәзер дә Фәтхулла абзый алдында кыен хәлгә тарыды. Нигә күрсәтергә инде аңа револьверын. Мактана, имеш…

— Аңа калса инде… Атып та караган юк соңгы араларда…— дип, аклангандай сөйләнде.

…Алар, абыйлы-энеле кебек күңелле сөйләшә-сөйләшә,

Фәтхулла йортына китеп барганда, көн кичкә авышкан иде инде. Ике-өч көн үтмәде, Әхмәтсафа бу йортка күченеп үк килде. Үги әнисе Шәмсия исә Әхмәтсафаны үз улыдай кабул итте. И дөнья! Кемнәр белән кавыштырмый, кемнәрне нинди хәлгә төшерми бу яшәү дигәннәре. Дөнья киң түгел икән. Бик тар ул дөнья дигәннәре. Шулай булмаса, әллә кайда, шайтан олаккан җирдә Фәтхулла абзый белән Шәмсия апайга юлыгыр идемени ул?..

* * *

Мөселманның ял көне — җомга. Якшәмбе — урыс көне. Һәр мөселман баласы намазга баскан көннән башлап белә торган гап-гади нәрсә инде бу. Әлмисактан ук килгән һәм бәхәс-мазарларга бөтенләй урын булырга тиеш кебек түгел дә... Әмма шушы ял көне мәсьәләсендә дә кайбер аңлашылмаучылыклар килеп чыга башлады соңгы вакытта.

Округ комитетыннан җибәрелгән циркуляр буенча ул «үтә яшерен» дип тамгаланган иде, Хивадагы хөкүмәт карамагындагы завод-фабрикаларда ял көне итеп якшәмбе билгеләнгән, ә җомганың эш көне итеп үзгәртелүе хакында әйтелеп, бу хакта эшчеләр арасында ныклы аңлату, үгет-нәсихәт алып бару зарурлыгы ассызыкланган иде. Сәбәбе дә күрсәтелгән: Үзбәкстан — СССР составындагы республика, үз-башка кануннар белән яшәргә тиеш түгел. Бөтен Совет иле бертөрле канун белән яшәгәндә, Үзбәкстанның аерым утрау хәлендә һаман шәригать кануннарына чат ябышып ятуы кискен тәнкыйть ителгән. Төп гаеп җирле фирка оешмаларының акрын кыймылдавында диелгән иде циркулярда. Мәскәү, аңа кушылып фирканең Үзбәкстан мәркәз комитеты милли мохтариятләрдә моның ише вак-төяк тайпылышларны тиз арада төзәтергә, моңарчы бу төбәктә яшәешне көйләп торган шәригать кануннарыннан тиз арада ваз кичеп, гомумсовет кануннары белән тормыш итә башлауны таләп итә иде. «Гомуми нормаларга китерү» дип әйтүе генә ансат, хәл күпкә катлаулырак иде шул.

Мәркәздән күрсәтмә-фәрманнар агылып кына тора, аларның дөрес яки хата булуын тикшерү урындагы фирка комитетының эше түгел. Боерык бар икән, аны үтәргә кирәк. Нинди күрсәтмә бирелсә дә!.. Фирка шулай гына яши ала. Шуңа күрә «ял көне» мәсьәләсен хәл итүгә дә җиң сызганып кереште округ комитеты. Әлеге гаять мөһим мәсьәләне контрольдә тоту Әхмәтсафа Дәүләтъяровка тапшырылды.

Мәскәү ерак, юлбашчылар Үзбәкстандагы хәлләрне бөтенләй белми торгандыр дип әйтә алмый Әхмәтсафа. Белә торганнардыр. Әмма ни дәрәҗәдә белә?.. Бу сорау аның

күңелендә юктан гына тумады һәм аңа төгәл җавап табу мөһим булыр иде. Әхмәтсафа фирканең үз эчендә эшне оештыруда зур чатаклыклар булуын сизенә башлаган иде. Шикләнергә, шөбһәләнергә сәбәпләр җитәрлек.

...Әле Хивага килеп, статистика-хәбәр бүлегендә эшли башлагач ук, аның белән Рәҗәпов арасында кискен сөйләшү булып алган иде. Ул сөйләшү хакында ни Әхмәтсафа, ни Рәҗәпов бер-берсенең исләренә төшереп тормасалар да, нәкъ шуның аркасында егетнең бүлектә эшли башлавына өч ай дигәндә, аны икенче урынга күчереп утырттылар. Яңа урын әүвәлгесеннән югарырак һәм үтә җаваплы булса да, егетнең күңелендә яра булып калды бу күчеш.

Әхмәтсафа статистика бүлегенә ел ахырында килгәнгә, еллык исәп-хисап ясап, бөтен мәгълүматларны мәркәзгә җибәрү дә аның өстенә өелде. Моңарчы җүнле-башлы исәп-хисап алып барылмаган бүлекнең эшен яңабаштан оештыру, ел дәвамында өзек-төтек җыелган статистик хисапларны барлап чыгу, аларны чагыштыру өчен кабаттан вилаятьләрдән мәгълүматлар китертү, якынча гына булса да еллык эшне дөрес итеп күзаллауга ирешү ниятен тормышка ашыру шактый көч һәм вакыт сарыф итүне сорады. Алсыз-ялсыз эшләү авырга туры килсә дә, ахыргы нәтиҗә сөенечле булды. «Тырышкан табар, ташка кадак кагар»,— ди иде әтисе мәрхүм, дөрес икән. Көне-төне шушы кәгазь боткасы белән әвәрә килеп үткәрсә үткәрде гомерен, әмма һәр тармак буенча, һәрнәрсәгә кагылышлы дөрес һәм төгәл мәгълүмат туплауга иреште бит, ә! Яңа хакимият урнашканнан соң, беренче мәртәбә округ җитәкчеләре өстәленә шундый төгәл, җентекләп хәстәрләнгән мәгълүматлар килеп ятсын әле! «Афәрин, егет икәнсең, Дәүләтъяров!» — дип, үзен мактый-мактый, билгеләнгән вакытта җавап тоту өчен, Рәҗәпов янына юнәлде ул.

— Йә, уртак Дәүләтъяров, хәлләр ничек бүлектә? Төшендеңме эшкә? Күреп тордык. Баш күтәрми эшләдең, мәгарәдә яткан акыл иясеннән ким кыланмадың,— дип, үсендергән шикелле кабул итте аны Рәҗәпов һәм, егетнең култык астындагы калын кенәгәгә күз салып, хәйләкәр генә каш сикертеп алды.— Чуар тышлы китап ни сөйли анда? Башка округ, өлкәләр алдында ничегрәк күрсәтә микән безнең хәлләрне?..

Әхмәтсафаның әле Урта Азиягә килгәннән бирле үз эшеннән шулай канәгать хәлдә йөргәне юк иде. Шаяртуга шаяртып җавап бирде:

— Китап нәкъ китап кушканча сөйләргә әзерләнде, уртак Рәҗәпов. Акка кара белән язылган, һәр саны мең дә бер кат тикшерелгән, һәр бите тамгаланган, мөһер сугып мәркәзгә җибәргәнне генә көтә. — Үзе әйткәнне дә көтеп тормыйча,

Рәҗәпов каршысына утырып, хисап тотарга әзерләнде ул. Тирән тын алып:

— Ел дәвамында округта...— дип, авыз ачып сүз әйтергә өлгермәде, аны Рәҗәпов кисәк кенә бүлдереп тә куйды:

— Тү-тү-тү, уртак Дәүләтъяров, кая ашыгасың, шаулап аккан арыкка төшкән өрек кабыгы шикелле. Каударланма әле син.— Рәҗәповның калын кашы җыерылган, йөзе кызарып чыккан, нигәдер тынычсызланган иде ул. Тиз генә барып бүлмә ишеген бикләп килде, аннан бераз тынычланып, акыл биргән сурәттә сөйләнә-сөйләнә кенәгәне битараф кыяфәт белән актаргалагандай итте.— Эш җаен белмәс көйгә мамык кәшәнкәсенә үрелгәч ни булганын беләсеңме? Кулсыз каласың, егеткәем! Исәп-хисап эшендә дә шулай, кулсыз гына түгел, башсыз калуың да ихтимал. Ашыгу пылау ашаганда гына әйбәт, инде эш эшләнгән, языласы язылган, сызыласы сызылган дигәндәй, тыныч кына сөйләшик әле. Мин синең хисап белән узган елгы күрсәткечләрне чагыштырып карадым. Күзгә чалынган ике-өч санга игътибар итүгә, йөрәк жу-у итеп китте, менә... Башсыз калабыз, уртак Дәүләтъяров, икәүләп башсыз калабыз болай булгач... Бер дә дөрес эшләмәгәнсең, кенәгәне киңәшләшми-нитми тутырып та куйгансың. Карап кына тормалы инде — чиста, пөхтә, бүген үк Мәскәүнең үзенә җибәр, иеме?..— Рәҗәпов чыраен сытып, урындыгыннан күтәрелде.— Әүвәл караламада гына эшләргә иде, аннан уйлашыр идек. Ашыккансың, уртак, ашыккансың...

— Монда барысы да дөрес! — дип кайнарланып, Рәҗәпов алдындагы еллык хисапны тартып алды егет. Гарьлегеннән нишләргә белмичә, җәһәт-җәһәт кенәгә битләрен актара башлады.— Һәр сан үз урынында, әйтәм бит, тикшерелмәгән бер сан юк дип. Һич тә борчылмагыз, уртак Рәҗәпов! — Ул ашыгып тәмәкесенә ут элде.

— Фирка комитеты раславын үтми торып, бер генә сан да дөрес була алмый, Дәүләтъяров. Төшенеп бетмәгән сабый кебек син. Дөрес сүзне фәкать фирка генә әйтә, дөрес санны да фирка генә белә, фирка генә юл күрсәтә. Без ул кушканны үтәүче генә. Син уйлаган дөреслек белән фирка фараз иткән дөреслек арасында зур аерма барлыгын исеңнән чыгарма. Хәзер үк күңелгә корт керде, менә син бу елда фәлән кадәр мамык җыелды дип күрсәтәсең...

— Мин күрсәтмим. Санны тикшереп, язып кына куйдым, чөнки чыны шул...

— Вәт, вәт!.. Кем язды соң ул саннарны? Син! Шулай бит. Димәк, әле бу диһканнарның эссе кояш астында тир түгеп, кул чиләрен чыгарып үстергән уңыш күләме түгел, ә син язган коры саннар гына. Конкрет саннар исә бөтенләй

башка нәрсә хакында сөйли, болай дип әйтә алар... — Аның юан бармагы өстәлдә яткан таушалып беткән кәгазь буйлап китте. — Узган ел тырыш диһканнарыбыз моның кадәр мамык уңышы җыеп алганнар. Салым-налог хисабына хөкүмәткә менә моның кадәр тапшырылган. — Рәҗәпов әйткән һәр санны авыз эченә йомып бара иде. — Ирекле бәядән дәүләткә фәлән кадәр сатканнар. Шулай, шулай... Башка күрсәткечләр ни сөйли анда?.. Каракүл тиресе шуның кадәр әзерләнгән, тәк, тәк... болары сатылган, дәүләткә тапшырылган. Ә синең кенәгә, үткән ел белән чагыштырып карасаң, капма-каршысын сөйли. Имеш, кайсын алма, быел нәкъ ике мәртәбә ким җитештергәнбез. Барысын да! Нәрсә, ел буе ефәк күбәләге куып йөримени округ комитеты?.. Бернәрсә эшләмәгән, бернәрсәгә җитәкчелек итмәгән, карамаган, күрмәгән, белмәгән дигән сүзме? Әллә саботаж ясап, советка каршы эш маташтырып ятканбызмы? Җавап бир, уртак Дәүләтъяров, мин төшенмәдем...

— Мин ... кабатлап әйтәм, уртак Рәҗәпов...

Рәҗәпов җилләнеп урыныннан торды, аннан шап итеп янә урындыкка менеп кунаклады.

— Син шул, син! Син генә монда, башка кешене күз чалымына да китермисең. Көн-төн халык мәнфәгатен кайгырткан округ комитеты да, безнең тамакны туйдырган диһканнар да, безне киендергән эшчеләр дә юк. Син бар менә, иеме?! Каян килә ул яшьләрдә шулкадәрле эгоизм?.. «Без» дип сөйләшәсе урынга, һаман «мин» дип тәкрарлый бит. Өлгермәгән йөземне җилпуч белән алга китереп утырттың да, инде хәзер, мәйлең, ашаңыз, уртак Рәҗәпов, дип торасыңмы? Миннән эш төште, калганын үзең кара, теләсә ни эшлә, дисеңме? Алай булмый, егеткәй. Ул саннарны кенәгәгә язганчы уйлар идең, башың булса. Алдагы елда бу диһканнар ничек яшәр, совет тарафыннан аларга нинди ярдәм күрсәтеләр? Уйладыңмы бу хакта? Юк шул, кешенеке кештәктә, диһкан кайгысы юк синдә, иеме? Менә бит ул ничек. Быелгы уңышка карап диһканга яренгә ашлама алырга мөмкинлек бирелә, сугару өчен ташлама ясала, кызыксындыру чаралары карала. Уңыш юк икән, бичара диһканга да бернәрсә дә юк, шымытыр башы тотып калачак. Төшенәсеңме, зирәк баш. Ә каракүл тирегә килсәк, ул — чүл алтыны, аны ким итеп күрсәтсәң, мал караучыларыбыз, чабаннар ни хәлгә төшәчәк? Күз явын алырлык бәрән тиреләре бездә генә, чыра яндырып дөнья буйлап китсәң дә, башка андый затлы каракүл тирене таба алмассың. Ким итеп күрсәтсәң, малчыларга да шымытыр башы, дөньяны өстерәргә рәт калмый дигән сүз. Күрсәткечләрдән чыгып, аларга хөкүмәт ярдәм күрсәтә бит. Ә ярдәмгә иң мохтаҗ кешеләребез — нәкъ менә чүл

алтыны — каракүл бәрәннәре тәрбияләп үстерүче фидакарьләребез. Сүзем тәмам, инде хәзер ни уйлыйсың? Син биргән саннарны җибәрсәк, ярлы-ябагайны кыен хәлгә куябыз, уртак Дәүләтъяров, төшенгәнсеңдер?..

— Тел төбегезне аңладым кебек. Тик бер генә нәрсәне төшенмим: еллар буе шул рәвешле «уңыш арттырып», күрсәткечләрне купайтып килгәнсез. Беренче игътибар иткән мәлдә белдексезлек кәсафәте дип кенә уйлаган идем. Хикмәт тирәндәрәк икән. Булмаган нәрсәне бар дип күрсәтүдән кем ота? Үзбәкстанмы, әллә, тулаем алганда, совет иленә берәр файда киләме? Әгәр бөтен ил күләмендә шундый купайтып күрсәтү чире башланса?

Рәҗәпов көлемсерәп куйды, тик дәшмәде.

— Моннан диһканнарга, чабаннарга да зур өлеш чыгар сыман түгел,— дип дәвам итте Әхмәтсафа.— Мин аларга күрсәтелгән ярдәм, ташламалар хакында да берничә еллык белешмә тупладым. Ләкин үсеш-үзгәреш сизелми. Кем елгыррак, кемнең округ комитетында таныш-белеше бар, шулар ярдәмне чумырып ала. Чыннан да, мохтаҗларга мыскаллап кына тәти совет ярдәме. Аннары дәүләткә, сәүдәгә озатылган һәрнәрсә чутсыз түгел ич. Без генә исәпләшмибез чынбарлык белән. Ялган барыбер ачылачак.

— Әй, Ходай бәндәсе,— диде ачынып Рәҗәпов.— Аларын кем санап-җыеп бетерсен, ди. Син болай язып җибәрәсең, Бохарада тегеләй төзәтәләр, Ташкентта алай, әле Мәскәүдә дә тере үзбәкне күрмәгән бер бәндә, Үзбәкстандагы хәлләр хакында җавап биреп утырадыр. Аның да диһкан әзерләп тапшырган мамыкка «кул тыгасы» килә торгандыр. А как же, җаваплы түрә бит ул! Ул да үзенчә төзәтеп утыра торгандыр. Һәммәсенә эш күрсәтү кирәк бит. Бәлки, безнең «күрсәткечләр» әллә кайчан хәзерләнеп беткәндер, уртак Сталинның яисә Бухаринның өстәле өстендә әллә кайчан ятадыр инде. Безгә эш тә калмагандыр.

— Алайса, нигә баш катырып утырабыз?

— Кызма, уртак Дәүләтъяров. Өлгермәгән йөзем ашап, эче киткән сабый кызганыч та, көлке дә. Шундый хәлдә калмыйк. Без Мәскәү өчен дә эшләмибез, башкасы өчен дә тире җыртмыйбыз. Үзебез өчен кирәк ул. Күрсәткечләрнең һәркайсысы узган елгыга караганда ун-унбиш процентка артык булырга тиеш. Округ комитеты шуны таләп итә. Дөресен белүчеләр бармак белән генә санарлык: син беләсең, мин, тагын Мөхәммәтәмин дигәндәй...

Әхмәтсафаның бирешәсе килмәде.

— Чынлыкта күрсәткечләр соңгы ике елда нәкъ сез әйткән кадәрле кими барган, еллык исәп-хисапта артым күрсәтелгән. Бу алдауның кайчан да булса «исе» чыгачак бит.

— Нәкъ өстенә бастың! Кайчан да булса... Иртәгә өчен ишәк кайгырган, уртак Дәүләтъяров. Без, конкрет алганда, бүген эшлибез, иртәгәге көн хакында да онытмыйбыз. Без күрсәткән саннар алар алдагы көннәр өчен ният-план булып торалар, изге ният ул. Төшендеңме? Без шул күрсәткечләргә йөз тотып эшләргә, диһканнарны, михнәткәшләрне-хезмәт иясләрен шуңа әйдәкләргә тиешбез. Башка округ, өяз, өлкәләр алдында йөзебезне җиргә орырга да тиеш түгелбез. Алардан ким эшләмибез, буй-сыннарыбыз да, акыл-фигыльләребез дә башкаларныкыннан ким түгел. Димәк, исәп-хисапны үзгәртеп, икенче кенәгә тутырырга туры килер. Менә сиңа үткән елгы саннар, күрсәткечләр, ә монысын миңа бир, өйрәнеп чыгыйм, кем әйтмешли, белми белмәүгә караганда, белеп белмәү яхшырак. Ә синең алдашу дип денең каткан... Алдашу түгел, эш тәртибе бу, илнең яшәү рәвеше... Ил матур ниятләр белән алга карап яши безнең. Халыкны шулай гына алга әйдәкләп була, беләсең килсә. Аң бул, уртак Дәүләтъяров, синең кулда көчле корал — каләм бар. Каләм үгез тарта алмаган йөкне дә тарта, белеп кенә куллану кирәк...

...Үзгәртеп эшләнгән еллык исәп-хисапны округ комитетында зур күтәренкелек белән расладылар. Әхмәтсафа җир тишегенә кереп китәрдәй булып утырды. Бигрәк тә чыгыш ясаучы җаваплы хезмәткәрләрнең, бер-берсенең күзенә туры карап, ялган саннар китерә-китерә нотык тотуларын авыр кичерде ул. Барысы да һәммәсен белеп торалар, саннарның «түшәмнән» алынганыннан һәммәсе хәбәрдар, әмма алдашалар, берсеннән-берсе уздырып, күзгә төтен җибәрәләр. Аның күз алдына әле өстәл астына көлтә-көлтә төтен җибәреп утыручы тук кыяфәтле Ниязов, әле тәрәз пәрдәсе артына зәңгәр төтен бөркүдән нииндидер сәер ләззәт кичерүче вәкарь Рәҗәпов килеп басты.

Рәҗәпов бу мәҗлестә шундый канәгать рәвештә утыра иде, әйтерсең ниндидер кодрәт белән чүл өстенә ике көннең берендә шаулатып яңгыр явып торган да, моңарчы ком бураны уйнап торган сахралар гөлбакчага әйләнгән дә куйган. Сәер халык, сәер ил, сәер дөнья...

Мәҗлестән алган авыр тәэсирләрдән арынып бетә алмый, эш бүлмәсендә уйланып, кул астындагы кәгазьләр белән әвәрә килеп утыра иде, коридорда ниндидер җанлылык, ашыгып сөйләшкән тавышлар ишетелеп алды, ул арада Җәмигъ мәчетенең имамы, Хиваның абруйлы хәзрәте, аның белән ике-өч дин әһеле килеп керделәр.

Имамнар керә-керешкә гозерләрен сөйли башламакчы иде, Әхмәтсафаны күргәч, бөтенләй күңелсезләнеп калдылар шикелле.

— Шушы япь-яшь нугай баласы белән ни генә гәпәрер-

без икән инде, ә, җәмәгать? — Моны алдан кергән баш имам әйтте. Башкалар авыр сулап аны җөпләгән булдылар.

— Болар кулына динебез язмышын тапшырсаң... — диде галәмәт олы чалмалы имам. — Читтән килгән байгыш башыңа кунса, сәмруг кош булыр. Килмешәк этне җиде мәхәлләдән куалар, аларга иркенлек бирсәң, ни буласын бүгенге хәлемездән чамала инде.

— Гыйлем — болак, акыл — чырак. Чеп-чи надан нугай имәстер күк...

— Наданның шунысы куркыныч: ул һәрнәрсәне беләм, ни эшкә тотынсам, шуны булдырып чыгам, дип уйлый, бахыр. Җиде йортның телен бел, җитмеш төрле белем бел, дигән гыйлем иярләре. Каян табасың хәзер андый белекле затларны? Бәс, дин-шәригать эшләренә казыйлык итүне шушы балага тапшырганнар икән, акыл казаны бөтенләй үк буш имәстер, берни эшләр хәл юк, гәпәрергә туры килер инде, — диде баш имам. Ул бу сүзләрне ничарадан бичара гына әйтте кебек.

Әхмәтсафа ишек катында торган имамнарның үзенә юллап атылган утлы сүзләренә артык игътибар итмәгән сурәттә, урыныннан кузгалып, һәркайсы белән ике куллап күреште, аларга урын тәкъдим итте, бергәләп озаклап дога кылдылар. Һәрхәлдә, үзенә төбәп әйтелгән сүзләр аның мин-минлегенә нык кына кагылып үткән иде, ләкин вазифа дигән нәрсә дә бар бит әле, кем дә булса тыңларга тиеш имамнарны. Юкны бушка аударып йөрүчеләр түгел алар.

Нугай егетенең үзләре белән үк бөтен шартын китереп дога кылуын күргәч, баш имам яктыра төште һәм округ комитетына килү сәбәбен тәфсирләп бирде:

— Балам, мөселманнар кимсенә бит. Изге җомга көнендә хөкүмәт эшенә килергә куша икән сәвит. Бу ни хәл, каян чыккан, кем чыгарган мондый канунны? Нинди иблис котырта мөселман әһеленә каршы сезләрне? — Имам, күзен чепиләндереп, зәһәр генә Әхмәтсафага карап куйды. — Син үзең мөселманмы, әллә урысларга сатылып, шайтан аздыруы аркасында юлыннан язган бер нәмәрсәме?..

Әхмәтсафа, имамның сүзләрен килештермәгән кебек, маңгаен җыерып куйса да, җитди итеп җавап бирде:

— Мөселман, хәзрәт, мөселман булам мин. Сез керер алдыннан гына динебезгә кагылышлы бер кәгазь укып утыра идем әле. Менә Татарстаннан бер документ бар.

Имам башкаларга аңлаткандай итте:

— «Татарстан» дигәне нугай иле була инде.

Калган икесе шаулашып алды.

— Аларга бер ышаныч та юк. Урысларга сатылып беткән адәмнәре.

— Аларның мөселманлыгын әйтерием инде...

— Алай димәгез, мөхтәрәм имамнар,— диде Әхмәтсафа, бәхәскә керергә тайчанмыйча.— Татарстанда милли республика буларак үз йөзен саклап калу, беренче чиратта, шәригать кануннары буенча яшәргә омтылу көчле. Менә бу документта да РСФСР Конституциясе белән шәригать кануннары чагыштырылып күрсәтелә, һәм, асылда, алар бер-берсенә каршы килмиләр икән. Сүз шул хакта бара. «Мөселманнар башка халыклар белән каршылыкка кермичә, үз тормышлары белән, шәригать кануннарына таянып яши алалар» дип раслыйлар әлеге документны хәзерләгән галимнәр. Шушы фикерне ныгыту максатыннан шактый күп мисаллар китерелә. Мәскәү моңа каршы килер сыман түгел, башка мөселман республикаларына да шундый яшәеш өлгесе тәкъдим ителә. Мәскәү хуплавы белән, әлбәттә. Димәк, хәлләр бөтенләй өметсез түгел сез әйткәнчә. Совет хөкүмәте бу хакта уйлана...

— Бәрәкалла, бәрәкалла, бирсен Ходай,— диде имамнарның берсе.— Аны кем язган, кем чыгарган соң? Ленин тамгасы салынганмы, мөһере бармы?

— Турысын әйтим, бу документ ике-өч ел элек килгән округ комитетына. Нигәдер аңа тиешле игътибар бирүче булмаган сыман. Югыйсә, документны өйрәнеп, тәкъдимнәрне Мәскәүгә җибәрергә тиеш булганнар. Төгәл әйтә алмыйм, тик белгәнемчә ул тикшерелмәгән, фикерләр Мәскәүгә дә җибәрелмәгән, ахры. Урындагы юлдашлар шулай диделәр. Ленин вафатыннан соң, аның васыятьләренә туры китереп эшләнгән ул. Шәхсән үзем, мөселманнарны пошындырган җомга көн мәсьәләсен хәл иткәндә, шушы документка таяначакмын.

...Асылда хәл җитди икәнен яхшы белә иде Әхмәтсафа. Хивада урыслар аз санда булсалар да, алар округ комитетында булсын, башка өлкәдә эшләүчеләрме — һәркайсы мөһим урын биләп торалар. Соңгы вакытта: «Ял көне җомга булырга тиеш түгел, совет илендәгечә — ял көне якшәмбе булсын!» — дип гауга чыгаручылар, җомга көнне эшкә килгән булып, якшәмбе көнне исә, ял итәбез дигән сылтау белән эшкә килмичә, хезмәт урыннарында ыгы-зыгы тудыручылар күренә башлады. Сәере — аларга башка милләт кешеләре, шул исәптән татар коммунистлары да кушылып, бер карауга әһәмиятсез дип күренгән хәрәкәт шактый тамырлана бара иде. Бу шаукымнан хатын-кызлар да читтә калмый, әле күптән түгел генә окружкомга мәркәз вәкиле булып Җамал исемле бер яшь кенә чая хатын килеп, зур җыелыш үткәреп китте.Үзе Коканд өлкә комитетында эшли икән. Бик ялкынланып, үтемле итеп сөйли. Аны тыңлаганда әлеге япь-яшь

хатынның кыюлыгына, тапкырлыгына хәйраннар калып утырды Әхмәтсафа.

— Җитте! Башны күтәрергә вакыт! — дип сөрән салды Җамал, чыгыш ясаганда. — Мин Казахстан баласы, Атбасар-Акмулла якларында беренчеләрдән булып пәрәнҗәне йолкып атып, яланбаш йөри башладым! Монда үзбәк хатыннарын, кызларын бәладән йолу өчен килдем. Салыгыз, хатыннар, пәрәнҗәләрегезне! Кызлар, якты кояш астына чыгыгыз! Күрсеннәр мөселман хатыннарының нурлы күзләрен, күрсеннәр гүзәл кызларыбызның йөзләрен. Шәригать безне күп изде инде, бетсен изү! Көчләү хурлыгы төрмә хурлыгыннан да яман. Безне мең еллар дәвамында шәригать исеме белән көчләделәр. Җаныбыз корыды, бәгырьләр кипте. Без шәригатькә түгел, шәригать кешелеккә хезмәт итсен! Шигарь шул булырга тиеш. Беренче адым — ял көнен якшәмбегә күчереп, җомга көнен эш көне дип игълан итик. Якшәмбе — хезмәт ияләрнең хезмәт бәйрәме булсын! — Яшь хатын, күкрәк киереп, иләмсез тавыш белән: — Ташлагыз пәрәнҗәне, Хива хатыннары! — дип кычкырганда, зур залда ялт-йолт яшен уйнап торган сыман тоелды. Бу кадәр тәвәккәллектән, кыюлыктан хәтта таш диварлар шаккатып калды, бина үзе чүгеп куйгандай булды.

Җамал Сарымсакованы шәһәр буйлап Әхмәтсафа озатып йөрде. Сарымсакова дигән саен, күңеленә аның Рабигасы килеп баса, ул да Сарымсакова фамилияле, ул да Атбасар ягыннан бит... Әмма бу янып торган карашлы, тыелгысыз рәвештә алга омтылган, ашкынулы адымлы хатын белән тыйнак, сабыр табигатьле, оялчан Рабига арасында нинди дә булса уртаклык күрмәде ул. Чибәрлек ягына килгәндә, әйе, Җамал төскә Рабигадан калышмый, бер тутырып карасаң, күзне алып булмый үзеннән, каһәр... Әхмәтсафа, тәвәккәлләп, Рабига хакында Җамалның үзенә сүз катмакчы иде, аның янып торган күзләренә карап алгач, кире уйлады, юк, аның Рабигасы әлеге мәркәз вәкиле белән беркайчан да туган була алмыйдыр. Холык башка, гамәл башка боларның.

Моңарчы да шәһәрдә хатын-кызлар хәрәкәте оештырганнар иде. Аны оештыручылар, билгеле, читтән ярдәмгә җибәрелгән коммунистлар, ир-ат халкы булды. «Ана» җәмгыятен дә ирләр оештырып, дилбегәне хатын-кызлар кулына тапшырдылар. Тик, өмет иткәнчә, Хивада бу хәрәкәтләр дөрләп кабынып китмәде. Бүген сүнәм, иртәгә сүнәм дип, пыскып кына азапланган хатын-кызлар хәрәкәтенә Җамал килеп киткәч, май сиптеләрмени, шәһәрдә пәрәнҗәгә каршы төркемнәр төзелеп, инде урамда пәрәнҗә ябынмаган мөселман хатын-кызлары да күзгә ташлана башлады. Онытырлык түгел иде аны.

...Имамнар исә Әхмәтсафаның сүзләреннән җилкенеп киттеләр, һаман гәп куерталар.

— Барлык милләтләр дә ил-көн алдында тигез булырга, үзе теләгәнчә көн итәргә тиеш! Ленин шуны гәпәрде. Без моны аңлыйбыз. Ә менә нигә дип мөселманга каныга бу урыс, һич төшенмибез, нугай баласы, ничек уйлыйсың, ә? Инде әмирдән яздык, халыкны зар елатып, хәкәрә китереп, дәүләтебезне таркаттылар, мәчетләребез изге гамәл — садака-зәкят алудан мәхрүм калып баралар. Һәрнәрсәдә тикшерү, һәр тиенгә ун тиен арттырып салым салына, кая бара бу дөнья? Әнә урыс теләсә нишләсен чиркәвендә, носариларда безнең эшебез юк. Аларның якшәмбесе — ял, безнең газиз җомгабыз — ял булсын. Аннан, ял көне дип, мөселман беркайчан да кул кушырып утырмады, җомга көнендә фарыз гамәлләрне кылгач, иҗтиһат итәргә тотына ул. Носарилар дуңгыз урынына эчеп ауный ул көнне. Сез, балам, мөселманны шушы носарилар хөкеменә төшермәкче буласызмы? Бер динне күтәреп, икенчесен юкка чыгарырга маташкан дәүләттән риза имәс без. Акылыгызга килегез, алар коткысына ияреп кагылмагыз мәчеткә, хатын-кызларыбызны хурламагыз, йөзләрен ачтырып. Нәмәхрәм эшкә өндәмәгез... Урыслар мәҗбүр итми бит безне бу эшләргә, үзләрен мөселман дип санаучы, асылда кяфергә сатылган адәмнәр мәҗбүр итәләр. Әйт әле, нугай баласы, коммунистның мөселманы, носарие, динсез-имансыз иблисе буламы?

Әхмәтсафа аптырап калды.

Имам, моны сизеп, һөҗүмгә күчте:

— Син үзең мөселманмы, балакай?

— Мөселман, дидем шикелле.

— Фиркале дәме?

— Фирка әгъзасы...

— Димәк ки, син мөселман коммунисты?

— Шулай булып чыга. Үземне денсез-имансыз кешегә санамыйм.

— Мәчеткә йөрмисең, намазга басмыйсың, фарызларны үтәмисең, нинди иман турында сүз алып барасың, төшенмим... — Имамның тавышы ачулы иде.

— Без, коммунистлар, иман калебтә дип саныйбыз, ә мәчеткә бару, намазга басу мәсьәләсенә килгәндә, дөрес, коммунист буларак бу эшләрне фарызга санамыйм.

— Урыс коммунисты чиркәүгә барамы?

— Дингә барлык коммунистларның да карашы бертөрле. Мин уйлаганча...

— Юк, балам, син уйлаганча уйламый ул носари коммунисты. Үзенең сүзе дөрес, синеке хак түгел дип уйлый ул. Син, иблис-шайтан коткысына бирелеп, башыңны урыс куе-

нына тыккансың. Ходай сине зиһеннән аерган. Әгәр урыс дәүләтенең кануннары шәригать кануннары белән яраша икән, кемнән куркып ятасың, ник мәчеткә йөрмисең?..

— Бу хакта әйттем инде...

— Телең шәп сөйли дә, күңелең каралыгын каплый алмый шул. Тагын бер кат уйла әле, менә син фирка тыя дип, җомга көн ял итмисең, димәк, тәмам динсезгә әйләнеп беткән мөселман коммунисты буласың, әйеме? Носари коммунисты исә, үз дине өндәгәнчә, якшәмбе көнне, ягъни воскресенье көнендә, Гайсә пәйгамбәрнең кабат терелгән көне, дип ял алып, тыштан күрсәтмәсә дә, эчтән, калебе кушканча, диндәшләре белән бәйрәм итә. Хәзер инде шуңа башка диндәге кешеләрне дә өнди, көчли, мәҗбүр итә. Димәк ки, шул рәвешле, мөселман калебенә дә носарилык иңә, ул шул канунга буйсынып яши башлый дигән сүз. Хаклыкмы бу? Ленин юлы шулмы?

— Уйлашырбыз, уйлашырбыз... мөхтәрәм имамнар, — дип кенә җавап кайтара алды Әхмәтсафа.

— Ай-һай, — диде көрсенеп баш имам, урыныннан кузгалган көйгә. — Сиңа, нугай баласы, уйларга калдырдылар микән инде носари коммунистлары. Чегән арбасына таккан дегет чиләге шикелле ияреп кенә йөрүчеләр түгел микән сез, балакайлар... Адашуыгызны үзегез дә төшенмисез, ахры...

Әхмәтсафа кулына төшкән документны тотып шактый йөрде. Тик аның сүзләренә колак салучы булмады. Барысы да округ комитеты циркулярына буйсынып эш итүне хуп күрделәр. Ял көне итеп якшәмбе көн игълан ителде. Ә РСФСР Конституциясен шәригать кануннары белән туры килүен раслап, Казанда хәзерләнгән документка килсәк, Мәскәү аннан күптән ваз кичкән иде инде, Ленин вафатыннан соң ук. Моны, әлбәттә, Әхмәтсафа белми иде әле...

* * *

Мондый рәхәт, җайлы тормышта яшәүне Әхмәтсафа онытып бара иде инде. Бирәм дисәң колыңа, чыгарып куяр юлына. Шәмсиягә, нәкъ Каргалыда дәшкәнчә, «инәй» дип дәшә ул. Үги әнисенең күңеленә хуш килә торган сүз булып чыкты ул әнкәй, инәй дигән сүзләр. Инәй сүзен ишеткән саен яктыра, канатланып, очынып китә. Хатындагы әлеге үзгәрешне Фәтхулла да сизә һәм Әхмәтсафаны үзләренә яшәргә алып кайтуына сөенеп бетә алмый. Ул гомерен эштә үткәрә, өйгә кайтып ризык җыеп китә алса, хуш, кайчакта кайтып керергә өлгерми, артыннан килеп тә җитәләр. Әхмәтсафа исә төшке ашка да өйгә ашыга, үги инәй хәстәрләгән ризыкларны авыз итеп, хәл алып китәргә гадәтләнде. Кич, эшләре

соң гына тәмамланган чакларда, якындагы тулай торакка кереп кунарга мөмкинлеге булса да, шәһәрнең аулак почмагындагы Фәтхулла фатирына кунарга кайта. Бу хәлгә Шәмсия бигрәк сөенә — Фәтхулла өйдә булмаган төннәрне үткәрү кыен аңа. Куркып, шомланып чыга төнне. Әхмәтсафа бер дигән иптәш — басынкы, тыйнак холыклы. Андый-мондый көтелмәгән хәл килеп чыкса, Шәмсия күреп калды — егетнең мендәре астында револьверы бар, бер дә җебеп төшәргә охшамаган, Шәмсияне дә, үзен дә яклый алыр, боерган булса.

Шәмсия, ни хәл итсен, Ходай бәби алып кайтудан мәхрүм иткән хатын, гел Мостафа агайның балаларын — үзенең үги улларын, теп-тере зәңгәр күзле Бибкәйне сөйләп, истәлекләр белән юанып гомер үткәрә монда. Ике сүзнең берендә Каргалыны, анда үткән тормышын сагынып телгә ала. Югыйсә сагынырлык тормыш кичердеме ул анда, җә?.. Туып-үскән яклар сагындыра икән шул. Анда күргән авырлыклар онытыла, тигәнәге гөл булып күренә башлый.

Ефәк тә генә билбау чите ука,
Чишәсем лә килми билемнән.
Туып-үскән илләр алтын бишек,
Никләр генә киттем илемнән?..

Ялгыз калса, күрше-күләнгә ишетелмәслек итеп, гел шушы җырны суза ул.

Әхмәтсафаның Хивага килеп, истә-уста юкта үзләрендә яши башлавына сөенде ул. Мостафа вафатыннан бирле, хатынның күңелендә авыр таш ята. Мостафаның үз-үзенә кул салуында хатын үзен гаепле санап яши, шул чаклар исенә төшә дә үзен каһәрли, битәрли башлый, күпме генә акланырлык сәбәпләр эзләсә дә, андый сәбәпләр юк, була да алмый. Ул никахлы ире Мостафага хыянәт итте, шул хыянәт аркасында Мостафа, балаларын калдырып, элмәккә менде. Белгәндер, сизгәндер хыянәтен. Мостафаның күңеле бик нечкә, үтә сизгер кеше иде ул. Урыны җәннәттә булсын, дип тә тынычлана торган гына түгел, китап мордар киткән кешене яратмый бит. Аңлашырга дисә, эч серен кемгә сөйли ала, кемгә нәрсә дип аклана ала соң ул? Ялгыз калган чакларда бу хакта еш уйлана Шәмсия. Кабат үткәннәргә әйләнеп кайта.

...Мостафа нигәдер аңа күңелен сала алмады. Болай караганда бар да хатын теләгәнчә булды: яучы да җибәрде, йолага туры китереп өйләренә алып та кайтты. Әмма ирнең басынкы, боек табигате үзгәрмәде. Нәрсәдәндер тартына идеме, әллә беренче, вафат булган хатынын оныта алмадымы, була бит җырдагыча, гомерлеккә бердәнбер ярга гашыйк булып, нинди генә хәлләргә тарыса да, шуны мәңге оныта ал-

мыйча яшәүче изге җаннар. Мостафаның үзенә карата чи-тенсенүле самими мөнәсәбәтен яшь хатын шулай гына аңлата ала иде. Югыйсә балаларны да үз итте, Бибкәйне бөтенләй үз кызы сыман якын күреп, куеныннан да чыгармады. Йорт эшләренә кулы чат ябышып тора, өйгә нур иңде, Шәмсия бусаганы атлап кергәч, әмма икесе дә көткән җан җылылыгы, бер-берсен үз итү була алмады.

Бер кайтуында, Шәмсия Мостафага зарларын түкте. Йорт эшләре күп, аның өстенә мал-туарны карап өлгер — ялгыз башың ничек җитешмәк кирәк?.. Хатынының елар дәрәҗәгә җитеп чәпчегәнен тыңлап торды-торды да дәшми-тынмый чыгып китте Мостафа. Өйлә намазына дип мәчеткә киткән җирдән үзе белән яшь егет ияртеп кайтты. Ул Тайфә түтинең улы — җиткән егет Хәлфи иде. Шул көннән йортта хезмәтче булып эшли башлады егет.

Мостафа тагын сәфәргә чыгып китте. Ни эшләсә дә, үз-үзенә зарланып йөрүдән туймаган бу чибәр һәм көче ташып торган егет — Хәлфи белән Шәмсиянең аралары көтмәгәнчә якынаеп китте. Бөтен эшне диярлек бергә башкарганлыктан, егеткә тиз иянде Шәмсия. Көннәр буе икесе бергә, ике яшь җан бер-берсенә тартылды, бер-берсен ярты сүздән аңлый башладылар. Еш кына карашлар очраша, очрашкан мизгел арасында күзләр бер-берсенә иң матур, иң ягымлы хисләр озатып өлгерәләр, кыскасы, яшь аермасы өч-дүрт елдан артмаган бу ике мәхлукның йөрәкләрендә чынлап мәхәббәт уты кабынып өлгерде. Гыйшык-мыйшык уеннары уйнап өлгерделәрме, юкмы, Шәмсия сизми дә калды, эшләр инде «кыйшык»та иде. Фәтхулласына бәби алып кайта алмады хатын, Мостафадан да балага узмады, күпме чуалып, Хәлфетдиннән дә йөкле булмады. Әмма ире өстенә хыянәт итеп яшәп булмавын аңлап, Шәмсия аерылу хакында уйлап йөри башлаган иде. Хәлфетдин, үзе дә күп ирләргә хас булганча, көймә комга терәлгәнче, ягъни кеше теленә кереп хур булганчы, авылдан чыгып олагу хакында уйга кергән иде, нәкъ шул чагында Шәмсия куркып калды кебек, эшне тиз генә хәл итә алмый азапланды. Ул арада дөньясы болганып китте. Егет үзенчә котылу чарасын тапты — кызылларга ияреп китмәкче булды. Шактый тәвәккәлли алмыйча йөрде. Акларга ияргә күңеле тартмады, кызылларның командиры Хәйбри усал иде шул, юлында очраган егет-җиләнне эләктереп ала да дезертир дип, таш келәткә ябып куя. Каршы сүз әйтүче, күрсәтүче булса, Сакмар буена чыгарып, солдатларына аттыра. Аннан Усманов дигән ягымлы комиссар пәйда булды. Ул килгәч, Хәлфине Шәмсия үзе үк кызылларга кушылырга күндерергә дип, егет яшеренеп яткан төшкә — сәндерәгә китте. Аларның өстенә шунда килеп чыкты инде Әхмәтса-

фа... Аңынчы да Госман белән бәрелеш булып алган икән, бу хакта аңа өстән-өстән генә әйтеп өлгерде Хәлфи. Бүтән чара юк иде, ике егет бергә Усмановка ияреп китеп бардылар. Менә бит тормыш ничек ул. Госман да кайтмады, Хәлфетдиннән дә хәбәр килмәде. Имеш, кайсыдыр якта аклар белән бәрелештә һәлак булган, диделәр. Тик Фәтхулла белән булган хәлдән соң андый сүзләргә ышанмый иде инде.

Шул көннән соң Шәмсия Әхмәтсафаның күзенә туры карый алмыйча йөрде. Болай озак яшәп булмый, Мостафа белән аерылышу хакында ныклы карарга килгән иде ул. Ләкин сүз башларга һич җай чыгара алмый интекте. Шулай бәргәләнеп, җаны кибеп, көннәр үтә торды. Тора-бара, Әхмәтсафаның авызыннан бер сер дә чыкмавына ышаныпмы, Шәмсия тынычлана төште, үз хәленә күнекте, аерылу хакында сирәк уйлый башлады. Аңа барыбер инде, яшәүнең яме киткән иде.

Көннәрнең берендә... Фәтхулла кайтып төште. Иренең кайтуын ишетү белән, ничек шулай булгандыр, алдын-артын уйламыйча, Шәмсия аның янына йөгерде. Елый-елый үзенең нинди хәлгә төшкәнен сөйләп бирде. Соңыннан Фәтхулланың «үлемен» Вәлкәй хаҗи оештырганлыгы билгеле булды. Фәтхулла бу хәлләрдән аптырап, алга табан ничек яшәргә дип уйланып, хыялланып йөргәндә, Мостафа үлеп китте. Фәтхулла бер авыр сүз әйтмәде, хатынның яралы бәгыренә тоз сипмәде, Шәмсияне кире өенә алып кайтты, никах яңартып яши башладылар. Шул ук вакытта Мостафаның балаларына да каты кагылмады. Бибкәйне үз кызыдай яратты ул, Әхмәтсафа белән Әхмәтханны да какмады. Әгәр ачлык елны Фәтхулла булмаса, бу сабыйлар исән кала алган булырлар идеме икән, Шәмсия ачык кына җавап бирә алмый... Миһербанлы, игелекле, шул ук вакытта курку белмәс кеше шул Фәтхулла.

Шулай да хатын Мостафаның үлемен авыр кичерде. Шушы көнгә кадәр ирексездән, үзен гаепле сизеп, күңелендә каты төер йөртә...

...Әхмәтсафа да әтисенең үлемендә үзен гаепле итеп яши. Яшьлек җүләрлеге дип атаргамы аны, олылар әйтмешли, әткәсенең башына ашкынуы микән, гает көннәрендә узынып алдылар шул ул елны. Кич яшьләр уены үткәрделәр. Яшь-җилкенчәккә нәрсә, кайда яңалык, кайда кызык — алар шунда. Ул кичне каравыл өе яшьләр белән тулы иде. Шәһәрнең якынлыгы, анда кайнаган мәдәни тормышның сулышы Каргалыга да килеп ирешә, яшьләрне җилкендереп, үзенә тартып тора иде. Халык мондый үзгәрешләрдән бөтенләй үк бихәбәр түгел иде, комсомолларның кыланышына артык чәүчәләкләп йөрүче дә булмады кебек. Волкомнан килгән вә-

кил, кайнарланып, яшьләрне гаеткә бармаска үгетләде, егетләр риза булып, соң гына өйләренә таралыштылар.

Иртән шул билгеле булды: ниндидер бәндәләр мәчет ишекләрен аркылы такталар белән кадаклап чыкканнар. Югыйсә барысы да белеп торалар: гаеткә каршы төндә мәхәлләнең иң диндар картлары мәчеттә төн уздыралар, тәһлил әйтәләр, китап кушкан йолаларны үтиләр. Әлеге көферлекне яшьләргә, аларны җитәкләп йөргән Саттар, Әхмәтсафа, Рәхимгә сылтадылар. Яшьләр үзләре аптырашта иде, бу эшне кемматаштырганын бик беләселәре килде килүен, тик очына чыга алмадылар. Артык зурга җибәрмәскә тырышып, эзләп-шаулап йөрүдән авыл түрәләре үзләре үк тыйды яшьләрне. Зариф абзый аны провокация, кешеләрне советка каршы кую өчен махсус оештырылган эш дип атады. Тик бу эшләрнең барысы өчен дә дин кардәшләре алдында нигәдер Мостафага — Әхмәтсафаның әткәсенә җавап тотарга туры килде. Вәлкәй хаҗи аны каргый-каргый мәчеттән куып чыгарды, бичара әтисе, икенче мәхәллә мәчетенә бармыйча, гает намазын өйдә укыды. Әле шушы хәлдә дә Әхмәтсафага күтәрелеп бәрелмәде. Улына каты-каты карап алуыннан, бүген булмаса, иртәгә, әмма нык кына сөйләшү булачагын аңлап алган иде егет. Эчке киеренкелек белән шул сөйләшүне көтеп йөргән чакта, үлем килде алар өенә... Моны егет авыр кичерде, чөнки Вәлкәй хаҗи, ачыктан-ачык, халык алдында: «Мостафаны коммун малае харап итте», — дип кычкырып йөргән.

...Әйе, уртак кайгылар, уртак кичерешләр һәм хәтта... уртак серләр берләштерә иде Шәмсия белән Әхмәтсафаны. Әхмәтсафа, үзләрендә яши башлау белән, үги әнисе, сеңлесе Бибкәйне дә үз яннарына алдыру хакында сүз кузгатты. Моны Фәтхулла күтәреп алды.

— Хивада кызлар мәктәбе бар. Аны тәмамлагач, кызлар гына укый торган педагогия училищесына бирербез. — Һәм инде хәл ителгәнгә санап кистереп әйтте. — Баланы җай чыгу белән алып киләбез. Йөрмәсен ятим булып, каңгырып...

Җай чыгарга тора — Әхмәтсафа инде ел ярымнан артык ялсыз эшли иде, аңа отпуск бирергә булдылар. «Отпуск» дигән сүзне беренче мәртәбә ишетүе булганга, башта Әхмәтсафа аптырабрак торган иде, вакытлыча гына килгән кешегә дә мондый ял биреләме, янәсе, аңа тиз төшендерделәр, сине монда вакытлыча килгән кешегә берәү дә чутламый. Син инде зур кеше, округта фирка җитәкчеләренең берсе, басылып кына эшләргә вакыт сиңа, канса да канис!.. Вакытлыча түгел дип саныйлар икән, анысы аларның эше, әмма Әхмәтсафаның күңеле Каргалыда — туганнары һәм, әлбәттә, Орен-

бурда калган кара күзле сөеклесе Рабига янында. Ул монда мәңгелеккә килмәде, ул үзе дә сагынудан кибә башлады, аны да сагынып көтеп торучы кеше бар, аның җаны шунда ашкына, күңеле шунда талпына иде.

Ә Бибкәйне алып килергә кирәк. Фәтхулла абзый дөрес әйтә. Укытырга, кеше итәргә кирәк бердәнбер сеңелләрен.

* * *

...Каргалыга кайтып килгәч, Әхмәтсафа шактый вакыт кадерле истәлекләр, хисләр эчендә йөзде. Шунысы әйбәт — ул август ахырларында гына кайтып җиткәнлектән, Рабига белән очрашып, сөйләшеп, вәгъдәләрне янә бер мәртәбә ныгытырга өлгерде. Чөнки Бибкәйне алып китәргә кирәк, шуңа Каргалыда озак юана алмый иде ул. Бибкәйгә укый башларга вакыт, болай да яңа ил, яңа иптәшләр, яңа вазгыятькә өйрәнү кыенга килер. Әгәр укуга соңга калып, иптәшләреннән артта калса, тагын да авыр булачак.

Рабига Әхмәтсафаның ашыгуын дөрес кабул итте. Тик егет шуны тойды: егерме яшькә җитеп килгән, бүген-иртәгә педагогия техникумын тәмамларга йөргән сылу кыз, билгеле, әллә кайда үзбәк дусларга совет хакимияте ныгытуда ярдәм итеп йөргән егетне көтеп ятмас, әгәр алдагы елга кайтып, кызны әләктереп калу, үзенеке итү мәсьәләсендә тәвәккәллек күрсәтмәсә, көт тә тор, Рабигадан коры калачак Әхмәтсафа. Рабига тирәсендә чуалырга маташкан шактый абруйлы егетләр барын ишеттереп өлгерделәр инде. Кызның оялчан гына үзенә карап, күз сирпеп алуларында да бу хакта ачык ишарә сизде ул.

Дус-ишләре инде шактый үзгәргәннәр, алар Әхмәтсафаны җитди егеткә санныйлар. Санарсың да. Элекке мутлыклар кимегән, сүзен үлчәп кенә сөйли, һәрвакыттагыча, һәрнәрсәгә үз карашы, үз бәясе бар, түрә булырга да өйрәнеп килә, ахрысы. Шулай да үзенекен генә тукып тормый, башкаларны тыңлый белә, аннан соң гына сүз әйтеп куярга ярата. Иптәшләренең үзенә карата хөрмәт белән карауларын тоеп, ул бераз кыенсына да иде. Дуслары да төшеп калган түгел ич: Муса Җәлил губернада күренекле шагыйрь, яшьләр җитәкчесе, аны белмәгән, чыгышларын тыңламаган кеше юктыр якын-тирә төбәкләрдә. Муса һәрвакыт уку, үсү хакында сөйли. Гайшә Мөхәммәдова Мусага шактый ачуланып хат язган, ул шуңа бераз үпкәләп тә йөри бугай. Аңлашыла сыман да. Муса Казанда чакта Гайшәне үз янына чакырган: «Кил, укуыңны монда дәвам ит, бергә-бергә күңелле булыр, мин инде Казанда танылган шагыйрь, абруй бар, исем бар», — дип, кызның башын әйләндереп бетергән.

Гайшә ТИНОны тәмамлау белән, ике дә уйламый, Казанга чыгып киткән. Муса исә юллама буенча Оренбур губкомы карамагына кайтып төшкән. Хәер, ике-өч ел туган якларында эшләп, авыл хуҗалыгын өйрәнергә ниятләве хакында ул Гайшәгә язып торды, башкалар да белә иде. Тик нигәдер Гайшә белән юллары аерылды да куйды шул.

Саттар Ишбулдин Үзбәкстанда икән, аның белән дә күрешеп өлгерде Әхмәтсафа. Саттар мәркәздә эшли. Дәрәҗәсен белеп сөйләшә һәм эшеннән бик канәгать иде, ахрысы, алдагы ният-хыяллары хакында ләм-мим, гел үзенең эше, иптәшләре турында сөйли, тиздән өйләнеп тә җибәрү икән исәбе.

Рабиганың үз кайгысы. Әтисе, дуамалланып, әнкәсе белән энесен өеннән куып чыгарган. Кызларының уку йортларында белем алуларына һич риза түгел, ата-баба йоласын, гореф-гадәтләрне аяк астына салып таптауларына әнисен — Хәлимә абыстайны гаепли икән. Быел җәйге ялы ял булмаган Рабиганың, йортсыз-җирсез калган әнисен юатып, җан асрарлык куыш табып, аз-маз кул эшләре белән утырып, теккән-чиккән, аларны базарда сатып акча эшләгән, әниләренә ярдәм итеп, булышып килгән. Инде алар өчен борчыла, алар өчен кайгыра. Әхмәтсафа кызның сыктауларын артык тыңлап тормады, үз сүзен өзеп әйтте:

— Әнкәңне иң элек Каргалыга китерик, Гомәрхан белән сөйләштем, торырга куыш булыр, абый кешенең өе иркен, эше дә табылыр, һәрхәлдә, тамаклары ач, өсләре ялангач булмас. Калганын мин кайткач хәл кылырбыз,— диде.

Рабига, егетнең сүзләренә куанып, беренче мәртәбә аның күкрәгенә сыенды.

— Нишләргә белми аптырап беткән идем шул,— диде ул, күз яшьләрен егеткә күрсәтүдән кыенсынып, йөзен читкә борды.— Киңәшим дисәм, апам Җамал Урта Азиядә... Безнең янга кайчан кайтасын үзе дә белми.

Җамал исемен ишеткәч, Әхмәтсафа Хивага килеп киткән мут, чая хатынны искә төшерде. Рабигадан сорамакчы иде. Нәкъ Хивадагы кебек үк күңеленнән Җамал белән Рабиганы чагыштырып карады да ачкан авызын кире япты. Ничек барысын да сөйләп торасың инде. Рабига әллә ни уйлар тагын. Җамал ачыктан-ачык егет белән кызыксынды бит. Форсат чыккан саен хатынның үзенә утлы караш ташлап алуын, егетне астыртын эзәрлекләвен хәтерендә яңартты да, юк, Рабига белән Җамал һич кенә дә апалы-сеңелле, бертуганнар була алмый, дигән нәтиҗәгә килде. Шулай булгач, хатын-кыз хакында сөйләп, кызның күңеленә вәсвәсә салуның кемгә хаҗәте бар? Мондый эшкә Муса һәвәс, ул сөйләргә ярата хатын-кыз хакында. Рабиганың исә күңеле болай да китек, хәле уеннан үткән. Яшерен-батырын түгел, Муса

Рабигага күз атып, сүз кушып караган каравын, әмма кыз кырт кискән: «Әхмәтсафага әйтәм, һаман-һаман тирәмдә тулгануыңнан туктамасаң, үзеңә үпкәлә!» — дип, тегене бераз шүрләтеп тә куйган. Муса, Әхмәтсафа исемен ишеткәч, сүзне шунда ук сәяси яссылыкка күчергән, имеш, аны кыз аңлап җиткермәгән, сүз бит яшьләрне губком тирәсенә туплау, актив комсомолкалар белән элемтәләр урнаштыру хакында гына бара. Рабига мондый эшләрдән читтә тормаска, активлашырга, үзен күрсәтергә тиеш. Киләчәк өчен мөһим нәрсә ул. Әхмәтсафа әле рәхмәт кенә әйтер, Рабиганың шундый кызыклы, актив тормыш белән яшәвенә. Кыскасы, боларны Рабига көлә-көлә сөйләде, әмма егетнең йөрәгенә ут капты. Муса хәйләкәр, күңеленә ятышлы кыз очраса, кармак салып карамый үтми инде, моңа Ченәкәй өйрәтте аны. «Кызлар алар күлдәге балык, кармак салмый үтмә,— ди иде ул мәхәббәт турында гәп куерта башласалар.— Эләксә, икеләнеп тормый тартып чыгар, эләкмәсә, җебеп утырма, кармакларыңны ал да икенче күлгә кит. Бер дә борчылма. Бер күлдә эләкмәсә, икенчесендә эләгер. Ниятенә кергәч, «балык» тотмый кайткан «балыкчы»ны очратканым юк, һәрхәлдә, кайсы күлдә «балык» булуы хакында хәбәрдар йөри ул шәп «балыкчы», кармак салырга җай гына көтә»,— дип көлә иде.

...Бу юлы да ул уйлаганча гына барып чыкмады. Кыш та үтте, яз да үтте, Әхмәтсафа инде Рәҗәпов янына ун гына кергәндер, тик аны эштән җибәрү хакында һич кенә дә уйламый тегесе. Бәхетенә, Рабигадан хат килеп төште. Кыз үзләре белән ТИНОда укыган берничә кешенең быел көздән Казанда, Татар коммунистик университетында укый башлаячаклары хакында әйтеп язган иде. Ходай биргән зирәклеге кушканмы, хат белән әлеге уку йортының адресын җибәргән иде. Әхмәтсафа күп уйламый ТКУ җитәкчесе исеменә укырга теләге барлыгын, мөмкин булса, чакыру җибәрүләрен сорап хат юллады. Округ комитетында эшләп, мондый нечкәлекләргә өйрәнә башлаган иде инде ул. Июль башларында чакыру килде, инде билгеләнгән тәртип буенча аны укырга китүдән беркем дә тыя алмый иде.

Моны Рәҗәпов та яхшы аңлый иде. Ул Әхмәтсафага бертуктаусыз эш өя, шелтәләп алырга да күп сорамый, аны хәтта ялкаулыкта, эшне белмәүдә гаепләүдән дә тартынмый, кыскасы, ничек тә егетнең укуга карата күңелен суытырга тырыша. Тисә тияккә, тимәсә ботакка, ди бит. Ике сүзнең берендә: «Сине Казанда көтеп торучы кеше юк, фиркагә җөнле-башлы файдасы тимәгән кешенең Казанга да керәге юк. Йөрмә, барма, Казанда сине укырга алмаячаклар»,— дип, егетнең күңелен төшереп азаплана иде. Әхмәтсафа, болар-

ның үзенә басым ясау икәнлеген яхшы аңлап, үзенең хак юлда икәнлегенә ышанычын какшатмады, укырга китү ниятеннән ваз кичү башына да кереп чыкмады, сабыр итте, түзде, чөнки белә, үзенең вазифаларын ул яхшы башкара, мәркәзгә җибәрә торган кәгазьләрне фәкать ул гына җиренә җиткереп яза, әле аның кулы аша үткән бер генә документ, язу өчен дә мәркәздән шелтә-мазар алганнары юк. Рәҗәповның нәкъ менә шуның өчен дә Әхмәтсафаны җибәрәсе килми. Егеткә талпан сыман кадалды. Кемдер әйткән бит, акылың булса, яхшы эшләвең өчен мактау, рәхмәт сүзләре көтмә. Зирәклегең, белеп эшләвең үз башыңа тимер чөй генә ул. Яхшы эшләүче, чүлдә гөлбакча үстергән диһкан кебек, тир түгә, гөлбакча үстерә, аны көннәрдән бер көнне сарык көтүе таптый да чыга. Кемне гаеплиләр дисеңме? Көтүчене түгел, әлбәттә, диһканны сүгәчәкләр, бакчаңны җүнле-башлы сакламадың, дип.

Инде Рәҗәпов, Әхмәтсафа Дәүләтъяровны тотып булмасын аңлап, бераз йомшарган булды.

— Ярый, мәйлең, Казан икән, Казан булсын, — диде ул, беркөнне егетне үз янына чакырып. — Без сине тотарга хакыбыз юк. Укуга теләгең көчле икәнлегеңне расладың, җитди кеше син, бушка вакыт үткәрмәссең. Укырсың, белем туплarсың, бәлки әле кире әйләнеп кайтырсың. Өйрәнгән яу сугышмаса яхшы. Көтәбез, кайт. Син бездә җитлеккән кадр.

— Әлбәттә, әлбәттә, уртак Рәҗәпов, — диде Әхмәтсафа куанып. Юкка ызгышып, җаны телгәләнүен бер дә өнәми ул.

— Менә килештек тә, — диде Рәҗәпов елмаеп. — Әйбәт кешеләр белән эшләве дә күңелле. — Ул бераз тын торгач, тәрәз янына килеп басты, гадәтенчә, авызына папирос кабып, ут элдерде тирән итеп эчкә суырды һәм тәмәке төтенен, нәкъ элеккечә, пәрдә артына өреп җибәрде, һәм көйле генә сүзен дәвам итте. — Бер эш килеп чыкты әле. Сиңа соңгы үтенеч тә дип аңла, фирка фәрманы дисәң дә була, Дүрткүл вилаятенә, Каштау кышлагына барып кайтырга кирәк. Яңа икътисадый сәясәт диһканнарга зур мөмкинлекләр ача. Алар дәүләт алып барган сәясәткә ышанып карыйлар хәзер. Безгә шул мөмкинлектән файдаланып калырга кирәк. Диһканнарны аерым яшәүдән йолып алырга кирәк, кооперативлар төзү мәсьәләсен кабыргасы белән кую лазем. Дәүләт хуҗалыклары — совхозлар төзү буенча да әйбәт эшлибез дип әйтә алмыйм. Диһканның зиһененә барып җитәрлек итеп сөйли, үгетли алмыйбыз. Фирка карарларын синнән дә оста аңлатучы булмас дип уйлыйм. Бер кышлакта эш башласаң, калганнарын игә китерү җиңел булыр. Кураның берсенә генә ут элеп җибәр, башкаларына тиз үрли ул.

— Моңа диһканнар ничек карый соң? Алар телиләрме

мондый берләшүне? Совхозларга ышаныч юк, диләр бит алар. Җирдән аерыласы килми диһканның.

— Фирка теле, фирканең ихтыяры бар, — диде Рәҗәпов, мәсьәлә хәл ителгәндәй. — Башка өяз, округларда хәлләрне ишетеп беләсеңдер. Инде совхозлар оешканга бишбылтыр, колхозларга берләшү бара. Ә Хорезм аксый. Ике аякка да аксый. Диһканнар белән эшләү ташка үлчим, хатын-кызлар һаман искегә ябышып яталар. Кирәк булса, мисал бар: бер яшь кенә бичә, иренә икенче хатын алып кайтырга рөхсәт сорап, тупсаны төшермәде. Бер хатын белән генә яшәү аның ире өчен хурлык булса, хатыны өчен иң зур кимсетелү икән. Менә аларның совет кануннарын аңлау дәрәҗәсе. Без яңа тормыш төзү хакында лаф орабыз... Уйлап бак, уртак Дәүләтъяров, Казанда сабакташларыңа нәрсә дип сөйләрсең, Урта Азиягә ничек килдем, шулай киттем, бер үзгәреш тә булмады, үзем дә булышлык күрсәтә алмадым, дипме?

— Үзгәрешләр шактый, уртак Рәҗәпов. Күрә белергә кирәк, иң мөһиме, халык тынычланып килә, хезмәткә кайта. Советка шактый ышанып карый, әмма ордым-бәрдем кыланып, бу ышанычны бик тиз какшатырга мөмкин. Арттан берәү дә кумый, без коммунистик җәмгыятьне мең еллар өчен төзибез. Уйлап, һәр адымны саклык белән атларга кирәктер. Юкса бер кулыбыз белән төзегәнне икенче кулыбыз белән җимерергә дә мөмкин ич.

— Сакланып дисең инде син. Саклану — куркаклык билгесе ул.

— Чынлап уйласаң, бернәрсәдән дә курыкмаган кеше үзе куркыныч ул... Андый кешенең җаны үз ихтыярында түгелдер кебек.

— Юкны сөйләп торма инде, Дәүләтъяров. Акыл сатарга оста икәнлегеңне беләм. Шуны аңла, мондый акыл фиркагә бер тиенгә дә кирәкми. Киресенчә булса, ул аны синең ише акыл иясәреннән потлап сатып алыр иде. Алмый бит, димәк, кирәге юк. Демагогия — бар эшне харап иткән иң явыз, мәкерле дошман! Мең еллар буе сеңгән диһкан күңеленә милекчелек, шуны мең ел буе куып чыгарыйкмы инде? Мең ел түгел, йөз ел эчендә дә әллә нәрсәләр булып бетә бу дөньяда. Тимерне кызуында сугу кирәк. Төшендеңме?

— Сезнең тел төбен төшендем. Тик мантыйкка сыймый, башлаган зур эшебезгә — яңа тормыш кору эшенең мәңгелек икәнлегенә ышанмыйча ничек яшәргә кирәк ди?

Рәҗәповның йөзендә нәфрәт дулкыны уйнап алганын күреп, Әхмәтсафа бәхәскә нокта куйды. Аның соңгы көннәрдә генә бу адәм белән ныклап ачуланышасы килми иде.

— Кайчан китәргә тиеш мин Каштауга? Кемнәр белән юлга чыгам?.. — Округ комитеты хезмәткәрләренә вилаять-

ләргә ялгыз чыгу тыела иде, Әхмәтсафа шушы хакта Рәҗәповка искәртте.

Рәҗәпов бераз уйланып торды.

— Башкарма комитеттан уртак Хуҗаев ике сакчы белән барырга тиеш. Әмма ул нindидер эшләр белән тоткарлана. Сиңа, күрәсең, үзеңә генә барырга туры килер. Дүрткүл белән сөйләштем, Каштауда диһканнар комитеты көчле дип ышандырдылар. Комитет рәисе Зәйнетдин әкә. Күргәнең дә бардыр, диһканнар мәҗлесләрендә бик төпле чыгышлар ясый торган адәм. Ышанычлы кеше. Заманында Әнвәр пашага каршы кулына корал тотып көрәшкән кызыл яугир.

Әхмәтсафа, күп сүз куертмыйча, фатирга кайтып, сәфәргә җыена башлады.

Шәмсия, Әхмәтсафаның берьялгызы җәһәннәм артындагы кышлакка җыенуын белгәч, чак елап җибәрмәде.

— Кая барганыңны чамалыйсыңмы, җүләркәй? Ялгызыңны кем җибәрә? Кемнең нинди үче бар синдә?.. Аяк та атлама, Фәтхулла абыең кайтсын, ул бер җаен тапмый калмас,— дип өтәләнде сөмсере коелган үги әнисе.

— Бармыйча ярамый, инәй.— Әхмәтсафа, Шәмсияне тынычландырмак булып, күтәренке тавыш белән сөйләнде.— Өч көннән мәркәзгә хисап тотарга тиешбез. Һавадан алып язып булмый, барырга, күрергә кирәк. Соңгы вакытларда вилаять-кышлакларга чыкмадым диярлек, гел өстәл артында кәгазь язып вакыт үткәрдем. Юлдан кайтып кермәгән кешеләр дә бар, алардан уңайсыз...

— Белмим, белмим,— диде хафаланып Шәмсия.— Өйләдән соң кем юлга чыксын ди?..

— Минем өчен шулай булуы әйбәт тә. Атым яхшы, монда килгәннән бирле бер ат. Холкы әйбәт, ияләнеп беттек берберебезгә. Әллә нинди хәлләрдә дә юл саташтырмый торган зиһенле җан. Затлы мал. Бүген Дүрткүлдә кунам, вилаятьтәге эшләр белән танышырмын, аннан иртүк Каштауга кузгалам. Ирәвәнләми генә барып җитәргә кирәк. Минем бурыч — Каштауда җыен үткәрү, диһканнар белән сөйләшү, халыкның хәлен белү. Шул гына, эш син уйлаганча катлаулы түгел, инәй. Иртәгә башка иптәшләр дә килеп җитәргә тиеш, бергә кайтырбыз.

...Сәфәр исә ул уйлаганга караганда да уңай башланды. Елкылдап торган туры атка, байтактан ерак сәфәргә чыкмавына рәнҗеп, аранда гомер үткәргән яшь айгырга, шул гына кирәк иде, юлга чыгып, Дүрткүл ягына борылуга, такыр юлдан алга томырылды. Ике сәгать вакыт үтсә үткәндер, Әхмәтсафа инде вилаятьтә үзен көтеп торган Зәйнетдин әкә белән иртәгә булачак җыен хакында сөйләшеп утыра иде.

...Һәр якның үз матурлыгы. Каштауга атларны кызулатмый гына барган чакта, Әхмәтсафа, бәлки, Хива якларына килгәч, беренче мәртәбәдер, игътибар белән тирә-юньгә күз ташлап, хозуранә хисләр кичерде. Ара-тирә битләрдә җиләс һава уйнаклавын тоясың. Бу якта сирәк бәхет — йөзне фирүзә җил иркәләп үтә. Бу — төш түгел, өн; бу — Амударья сулышы. Җиһанга ямь биреп, яшәүне ләззәтле иткән ике генә нәрсә бар: берсе — кояш, берсе — су. Һәрхәлдә, чүлдә гомер кичергән кавемнәр шулай уйлый. Тик чүлдә кояшы хәттин ашкан, суга исә мәңгелек кытлык. Ходайга бәндәләрен болай тилмертү, сынау нигә кирәк булгандыр, үзе генә белә. Хәер, кай якка барып чыкма, шул хәлдер: бер җирдә халык суыктан интегә, кар-бураннардан җәфа чигә, икенче җирдә туктаусыз җил-зилзилә, су басулар, өченче җирдә халык сусызлыктан әлсери, кояшның рәхимсез нурлары астында тилмерә. Яшәү дигәннәре тоташ бәйрәмгә әйләнмәсен дип тырыша торгандыр инде Ходай. Гомер кичү тоташ бәйрәм түгел шул. Ел фасылы алышынып торган кебек, кичергән хисләр дә бертөрле генә түгел. Кеше күңелендә мәңгелек шатлык булмаган кебек, гел хәсрәт-ут йотып кына да яшәми адәм баласы. Чиктән ашып сөенмә, чиктән ашып көенмә. Яшәү кануны урталыкны сайларга куша. Менә Рәҗәпов үзенчә Әхмәтсафага бер этлек эшләп алды, бүген-иртәгә туган ягына кайтып китәсе кешене ерак сәфәргә чыгарып җибәрде. Мондый хәлдә нишләргә тиеш ул? Акылы сәламәт бәндә борчылырга, чәпчергә тиеш инде. Тик егет үзен тынычландырды: әгәр юлга чыкмаган булса, шушы хозурлыкны күрер идеме ул? Юк. Аның өчен Хива яклары матур яктан ачылмый калыр иде. Димәк, Рәҗәповка төшәсе рәнҗү хисен сөенеч, канәгатьләнү хисе алыштырырга тиеш.

Иртүк юлга кузгалсалар да, кояш алардан өлгеррәк булып чыкты, бераз күтәрелеп, тирә-юньгә күз ташлады да, галәмдә үзенә тиң таба алмавына үртәлгән кебек, җирне рәхимсез кыздыра башлады. Баш өстендә — кучкыллы зәңгәр күк. Җирдәге һәр җан иясенә, һәрнәрсәгә битараф һәм гамьсез карый ул. Баягы куанычлар чигә төште. Әхмәтсафаның тойганы булмаган икән — башын күтәреп, күк түрләрен карашы белән айкап алган иде, хәйран калды — югарыдан аңа өметсез бушлык текәлгән. Җанны ут ялмап алды кинәт. Табигатьнең бу халәте адәм балаларының бер-берсенә мөнәсәбәтенә охшаш иде. Кайбер адәмнәр, югарыга менгән саен, түбәндәгеләрне онытала бит. Түбәндәгеләрнең эш-гамәлләренә, сөенеч-шатлыкларына, кайгы-хәсрәтләренә тома битараф була башлыйлар.

...Бара торгач, тиз агышлы елгага җиттеләр. Елганың

ике яры чаукалык, яшь таллар сырып алган. Эчтә эрерәк агачлар да күзгә ташлана. Монысы Сакмарның урманга күмелгән сул як ярын хәтерләтә. Чаукалыкта кошлар сайрый, ишеткәне бар, имеш, җәй уртасы үткәч, кошлар сайраудан туктыйлар икән. Туктый ди сиңа, бер генә тын торыгыз әле, нинди генә кошлар сайрамый да нинди генә авазлар ишетелми монда. Хәер, әлеге гүзәллеккә тап булсаң, үзең үк сайрый башларсың. Әхмәтсафаның күңелен ашкынулы хисләр биләп алды. Төбе әкәмәт тигез итеп ташлар белән түшәлгән шушы елга буенда, толымнарын алкын суга салып, рәхәтлеккә оеп утырган яшь таллар арасында качыша-качыша уйныйсы иде. Кем белән дисезме? Әлбәттә, сөйгәне, Рабигасы белән инде. Хыялдан шәп нәрсә юк, баш миенең иң серле гамәле дә хыялдыр. Әхмәтсафа мизгел эчендә хыялы белән Рабиганы үз янына алып килде, бергәләп ат өстендә йөрделәр, елганың боздай салкын суында битләрен юдылар, арган тәннәренә дәрман алдылар, су чәчрәтеп уйнадылар, озаклап чаукалыкта уйнап-шаярып, сабый балалардай чыр-чу килештеләр. Рабиганы күр син, оялчанлыгын, кыюсызлыгын шушы елга суына агызып җибәрде, ахры, бөтенләй тартынусыз Әхмәтсафага килеп сыена, егетнең чәчләреннән сыйпый, иркәли. Ә үзе коңгырт матур күзләрен каядыр биеккә, күккә төби. Әхмәтсафа исә, моны килештермәгән кебек, бераз көйсезләнеп: «Миңа гына кара, күзләреңне миннән алма, бәгърем»,— дип үрсәләнә. Егетнең зәңгәр күзләреннән сагыш, шөбһә түгелә. Күңеленә хуш килмәгән битараф, төпсез күккә каратасы килми ул аны. Нindидер гамьсез өермә уйнап алыр да, Рабигасын кулыннан йолкып алып, әллә кайларга илтеп ташлар кебек... Шуның өчен китердеме ул аны шушы гүзәл елга буена?.. Рабига исә аны ирештереп: «Нигә карамыйм ди, тиле егет! — дип чыркылдап көлеп җибәрә.— Җир безнеке, күкләр дә безнеке. Җиһан, галәм безнеке! Ә менә син — минеке, минеке генә!» — дип, егетнең муенына сарылып, кысып кочаклап ала. Әхмәтсафа, ашкынып: «Ә син — минеке!» — дип, кызны күкрәгенә кыса...

Шундый ләззәтле уйлар эчендә йөзгәндә, аны Зәйнетдин әкәнең кычкырып әйткән сүзләре айнытып җибәрде:

— Алдагы таулыкка күтәрелеп төшкәч, безнең кышлак инде, уртак Дәүләтъяров. Ходай уң кылгач, менә килеп тә җитәбез.

Татлы уйларыннан аерганы өчен Зәйнетдин әкәне рәхәтләнеп бер тиргәргә иде дә, «уртак Дәүләтъяров» дигәнне ишетеп, Әхмәтсафа елмаеп куйды. Уртак Дәүләтъяровның нинди хыяллар эчендә гизгәнен белсә, ике дә уйламый: «И сабый, сабый, син карый булып җиткәнче...» — дияр иде әкә...

Каштау диһканнарына алдан әйтеп куйганнар булса кирәк, зур гына амбар сыман җиргә шактый кеше җыелган иде. Каштауга килеп җиткәч, озак юанмадылар, Зәйнетдин әкә, комитетның берничә актив әгъзасына ниндидер әмер биреп каядыр озаткач, Әхмәтсафага кышлак хәлләрен сөйләде. Болай тыныч кына яшәп ятучы кышлак икән ул. Өчдүрт еллар элек хәлләр мөшкел булган. Диһканнар авырлыклар кичергәннәр. Озын җәй буе тир түгеп үстергән мамыкны дәүләт талап диярлек алган. Бәяләр арзан; мамыкны бирми, көтеп торырга уйлаган диһканның өенә гаскәриләр кергән... Алар инде буш кул белән чыкмаганнар. Игенне дә талап алу гадәткә кергән. Шушы хәл диһканнарны яңа хөкүмәткә каршы куйган. Күпчелеге элекке әмирлек чорын сагына башлаган. «Гөнаһысына керергә кирәкми, әмир диһканга яшәргә мөмкинлек бирә иде», — дип уфтанып куйды Зәйнетдин әкә. Шөкер, соңгы елларда мондый талау сәясәте йомшара төшкән, халык белән киңәшләшеп, килешеп эшләргә өстенлек бирелә башлаган. Шулай да диһканнар комитеты һәрнәрсәне үзенчә хәл итә алмый икән әле.

— Электән үк кышлакта үз сүзен сөйләтә, үз җыруын җырлата торган адәмнәр бар иде. Хәзер дә бар алар, халыкны хакимияткә каршы котырталар,— диде Зәйнетдин әкә, Әхмәтсафаның чокырына чәй коеп.

— Ниндирәк дәлилләр белән коралланган соң алар?

— Советлар, алдап, төрле хәйлә кулланып, үзбәкләрне басым астында тотмакчы булалар, денсезлеккә өндиләр дип сафсата саталар. Имеш тә ки, советка хезмәткә керүчеләр ата-баба йоласын җиргә салып таптыйлар, гореф-гадәтләрне санга сукмыйлар. Моннан берничә ел элек кышлакка бер мулла килеп төпләнгән иде. Зәһәр нәрсә, сүзен бирмәс өчен, әллә ни кылырга да әзер. Гыйлемлеге дә бар, инкарь итеп булмый. Нугай адәме. Халык әүвәлге елларда аның авызына гына карап торды,— дип дәвам итте Зәйнетдин әкә.— Урысча да шәп белә. Телендә нугай, казах сүзләре күп. Бик үҗәт кеше, диндар болай карап торуга. Эчтән ничектер, анысын Ходай белә. Чи итне чыгарды ул безнең. Диһканнар комитеты башлаган һәр эшкә аркылы төшә, кем әйтмешли, авызыңны ачып торсаң, чылтырап агып яткан арык юлын бикли дә куя.

— Каян килеп чыкты соң ул? — дип кызыксынды Әхмәтсафа.— Шулай тиз генә кышлакны үз кулына ничек ала алды?

— Кызыл нугайлар безнең муллабызны — ишан хәзрәтне атып киттеләр. Әнвәр паша кешеләре белән элемтәдә булып, советларга каршы эш алып барган дип. Озак та үтмәде, сәүдә белән киткән кешеләребез чалма-чапанлы, үткен бер

адәмне ияртеп кайттылар. «Шушы кеше муллабыз булыр!» — диделәр. Кем каршы төшсен? Мулласыз, шәригатьсез яшәп булмый.

Зәйнетдин әкәнең алдан сөйләп куюы мәҗлес-җыен вакытында ярады тагын. Әхмәтсафа чәйханә алдына җыелган халыкка үзенең килү сәбәбен аңлатып, алга табан ничегрәк тормыш итү хакында округ комитетының уй-ниятләрен бәян итеп, шулар хакында диһканнар белән киңәш сурәтендә әңгәмә кора башлаган иде, арадан берсе, алгарак чыгып, бу хакта артык җәелергә бирмәде:

— Хивадан килгән кунак мөһим эш белән йөри, үзе дә каршы імәстер, дип уйлыйм, мондый зур сөйләшү-гәпне әүвәл Коръән Кәрим аятьләре белән башласак, яхшы булыр, — диде.— Ходайдан узып кылган гамәлдән хикмәт чыкмас. Бисмилласыз башланган сүз зиһенгә барып җитми, аны шайтан эләктереп ала да аңда буталыш тудыра. Бераз гына сабыр кылыйк, муллабыз килеп җитсен, мәҗлесне башларга фәтва бирсен. Хивадан килгән вәкилне ул да тыңласын. Кунакның тел төбен аңладык, диһканнарны берләштерергә, җирләрне бергәләп эшкәртергә, арыклардан күмәкләп файдаланырга өнди. Инде безне тыңласын. Бу әле сүзгә керешү түгел, болай гына... Уйларга җирлек бар, әйтик, Фәйзулланың җире кештәктә, Насретдинныкы гарештә, Бикмәтнеке мәгърибтә, Алимныкы мәшрикъта. Мөмкинлеге булганнар үз җирләрен үзләре хәл кыла. Катлаулы, четерекле мәсьәлә бу. Бер җыенда гына хәл кылып булырмы? Муллабызга безнең исемнән сөйләргә вәкаләт бирик. Без аңлап җитмәгән нәрсәләрне ул төшендерер. Сәвит кешеләре белән сөйләшүләр алып барырга булышлык күрсәтсә, начар имәс. Безнең файдага гәп кылды моңарчы, Ходай аңа савапларын бирсен.

Ул да булмады, ишектә чалма-чапанлы дүрт-биш адәм пәйда булды. Халык арасында:

— Мулла килде, юл бирегез, үткәрегез,— дигән сүзләр ишетелде.

Җыйнак гәүдәле, зур чапанлы кешенең мулла булуында шик юк иде. Беркемгә дә күз салмый, гаять иркен рәвештә халык арасыннан алга табан үтүе, үзе өчен махсус җәелгән киезгә илтифатсыз кыяфәттә аякларын бөкләп утыруы (кунаклавы дисәң дә дөрес булыр, чөнки ул моны бик тә җәһәт һәм гадәти башкарды), халыкның Хива вәкилен дә онытып, аңа күз текәп, тын калуы мулланың чыннан да абруе зур икәнен сөйли иде. Үзбәкләр мулла дип дин әһелен генә түгел, абруйлы һәм белекле, күп нәрсәләрдән хәбәрдар, белгәннәрен уңыш белән гамәлдә кулланучыларны да атап йөрткәнгә, Әхмәтсафа, кызыксынып, каршысында утырган кеше-

гә күз салган иде, күкләр ишелдемени, җир чайкалып, бераз-га башы әйләнеп, зиһенен җыя алмый торды, аның каршында бәбәкләрен аска текәп, иманга оеган төстә утырган адәм — кайчандыр Каргалыдан эзсез-нисез юкка чыккан Вәлкәй хаҗи иде...

Ул чорда илдә дин әһелләрен, шул исәптән мулла-хәзрәтләрне эзәрлекләү башланган иде. Вәлкәй хаҗиның кисәк кенә юкка чыгуына хафаланган кеше дә булмады бугай. Шулай да ниндидер хәбәрләр килеп ирештe тагын. Кемдер азанчы хәзрәт Төркия ягына чыгып сызган дип сөйләде, кемдер хаҗиның Зәки Вәлиди янына, Стәрлетамак яклары-на китеп эзен чуалтуы хакында хәбәр ирештерде. Әмма ул чактагы болганчык дәвердә бу сүзләргә берәүнең дә исе китмәде. Әхмәтсафаларның бигрәк тә борчулы көннәре иде. Әтисе Мостафаның аянычлы үлеме һушсыз иткән иде, хаҗи кайгысы булмады аларда, Вәлкәй исә нәкъ менә әтисе үлгән көнне юкка чыкты бит...

Әхмәтсафа, үзен кулга алырга тырышып, Зәйнетдин әкәгә:

— Әйдәгез, әкә, дәвам итик,— дип дәшкән иде, Зәйнетдин, ашыкма дигәнне белдереп, Әхмәтсафаның беләгенә сак кына кагылып алды.

Егет үзен табага куырырга салган ясмыктай хис итте. Иң кыены: кечкенә өстәл артыннан җәһәт кенә сикереп торып, Вәлкәй хаҗиның — Каргалының карагруһ, миһербансыз кешесе, авылда чакта мәзинлектән үтә алмаган, шуның өчен мәчет тирәсендә ел саен тавыш чыгарып мәш килүче үчлекле бер адәме, үз сүзен сүз итү өчен теләсә нинди нәҗеслеккә бара торган затсыз бәндә икәнен дә әйтә алмый. Вәлкәй хаҗи мондагы халыкның гадәтләрен, холык-халәтен яхшы өйрәнгән, Әхмәтсафаның бер сүзенә ун сүз белән җавап кайтарачак, җитмәсә, борын-борыннан диһканнарның үтә нык дини рухта булуыннан файдаланып, һәр сүзен Коръән аятьләре, хәдисләр белән нығытып барачак. Әхмәтсафаның бу мәсьәләдә, сүз дә юк, белеме дә, тәҗрибәсе дә бәләкәй. Ул күбрәк фирка сүзе сөйләп чарланды. Бәхәсләшергә оста иде Вәлкәй хаҗи, һай, оста иде. Каргалыдагы һәртөрле ызгышның үзәгендә ул, мәхәллә имамнары арасында барган каршылыклардан оста файдаланып, дин-мәчет эшләрендә үз сүзен үткәрүгә ирешмәктә иде. Күрәсең, әлеге сыйфатлары Каштауда аңа ифрат файда китергән, халык, әнә ничек табынып, интизар булып, хәзрәт белән бергәләп озаклап дога кыла. Әхмәтсафа да, башкалардан калышмаска тырышып, шартына җиткереп дога кылды, әмма Вәлкәй хаҗи һәммәсеннән дә озаграк укыды. Хәзрәт эргәсендәгеләр берничә мәртәбә хәзрәтнең тартылып куюын күреп, бит сыпырырга ният дип аңлап, кушырылган кулларын йөзләренә якын китерделәр.

Әмма хаҗи ашыкмады, бирелеп дога укыгандагы сыман иреннәрен кыймылдата бирде. Вәлкәй хаҗиның астыртын көлемсерәп, иреннәрен чалыш-молыш китереп утыруыннан аңлап алды егет — хаҗи халык белән, шул исәптән каршысында утырган Хива вәкиле белән дә мәчеле-тычканлы уйнаган шикелле итә иде.

Шунысын да тотып алды Әхмәтсафа, Вәлкәй хаҗи иманга оеп кына утырмый инде, вәкил булып килгән егеткә күз ташлаган уңайга нигәдер кисәк алга тартылып куйды, янә берничә мәртәбә егеткә сынап-сынап карады, йөзе күм-күмгәк булып чыкты, аннан бераз дога укып утыргач, тынычлана төштеме, авыз читендә сәер елмаю хасил булды.

Догадан соң Вәлкәй хаҗи, Зәйнетдин әкәгә баш кагып, җыенны дәвам итәргә рөхсәт бирде.

Зәйнетдин әкә озаклап кышлак хәлләре, Дүрткүлдә ишеткән-күргәннәре хакында ялыктыргыч нотык сөйләргә тотынды. Вәлкәй хаҗи исә, бертын алга иелә төшеп, уйлагандай итеп утырды да, янәшәсендәге табак битле чалмалы адәмнең колагына нидер пышылдарга, бер караганда ашыга төшеп, икенче караганда тыенкы һәм тәфсилле рәвештә аңа нәрсә хакындадыр аңлатырга, төшендерергә тотынды. Теге адәм башта тутырып Әхмәтсафага агулы караш ташлады, аннан Вәлкәй хаҗиның сүзләреннән үтә сөенгәндәй, бөтен йөзе белән елмайгандай итте. Әмма әлеге елмаю зәһәр һәм шулкадәр нәфрәтле иде, Әхмәтсафаның ирексез йөрәге кагып алды. Икеләнерлек урын юк, Вәлкәй хаҗи үзенең каршысында утырган егетнең авылдашы Мостафа малае икәнен танып алган иде.

Соңгы елларда ул Мостафа агайга, аның балаларына шулкадәр үчлекле булды, хәтта эзәрлекләргә үк тотынды дисәң дә ярый: вафат булыры алдыннан әтисен шушы Вәлкәй хаҗи котыртуы буенча куштаннар ничек кенә мәсхәрә кылмадылар да, ничек кенә рәнҗетмәделәр. Гаҗәбе шул, кай якларга килеп чыкса да, Вәлкәй ишеләр үзләренә куштан табалар икән, башларында туктаусыз бөтерелгән мәкерле ниятләрен алар аша тормышка ашыралар. Менә хәзер дә, иманы камил, Вәлкәй хаҗи, үзенең куштаннарына Әхмәтсафа хакында яман нәрсә сөйләп, аларны егеткә каршы өстереп, котыртып утырадыр. Вәлкәй хаҗины яхшы белгәнгә, башкача булуы мөмкин түгеллеген шулай ук тиз төшенеп алды Әхмәтсафа.

Башында уйлар чабыша иде егетнең. Вәлкәй хаҗи ни эшләргә җыена? Әхмәтсафага сөйләргә ирек бирерме аның куштаннары, юкмы? Сөйләгәндә, каршы төшеп, бүлдереп, фикерен бутап бетерсәләр, хәлдән ничек чыгарга?.. Мантыйк буенча китсәң, күрәсең, ул Хивадан килгән вәкилне, кем бу-

луына карамастан, тыңларга тиеш. Чөнки округка кайтуга ук, советка каршы үгет-нәсихәт алып баручы Каштау мулласы хакында сүз кузгатачак, вәкилгә каршы килү — Зәйнетдин әкәнең кылган эшләренә астыртын аяк чалып, халыкка коткы таратып яту гына түгел, тиз эзенә төшәчәкләр. Бүгенге җыенда ул ачыктан-ачык каршы сүз сөйләмәс, ә менә Әхмәтсафага каршы ниндидер астыртын гамәл кылмый, ай-һай, җибәрер микән? Җыен бетүгә, Әхмәтсафаның исәбе — Каштауда озак юанмау иде. Дүрткүлгә, атны артык куаламыйча да, өч сәгать чамасында барып өлгәшә ул. Бүген Дүрткүлдә кунып, иртәгәсен, бик каударланмыйча гына, Хивага кайтып керәчәк. Төштән соң шушы сәфәре хакында хисап язып тапшырырга да шуның белән вәссәлам, эшне калдырып, атна-ун көннән Каргалыга карап юл чыгарга булыр кебек. Насыйп булса, август урталарында ул инде Каргалыда, тагын берничә көннән соң Казанга кузгалыр. Кулында укырга чакыру кәгазе булган хәлдә, Хивада аны берәү дә көчләп тота алмый. Үзбәкстанда совет хакимиятен үзбәк дуслар үзләре җаннары теләгәнчә урнаштырсыннар, Әхмәтсафа булдыра алганча тырышты, кем әйтмешли, һаман да карусыз малай хәлендә йөрүне күз алдына да китерә алмый. Ярый әле, үҗәтлек күрсәтеп, Казанга язып җибәрде, юаш булсаң, басарлар, баш бирмәсәң, асарлар, дисәләр дә, бу дөньяда үзең өчен көрәшмәсәң дә булмый икән. Әхмәтсафа шуны төшенде, фирка исеме белән теләсә нинди әшәкелекләр эшләргә мөмкин хәзерге вазгыятьтә. Җитәкчелеккә дә зирәклеге, эшкә сәләте буенча түгел, уйнаш кылырга яратучылар җыела бара. Егетнең бөтен күңеле әлеге хәл белән килешми, болай булмаска тиеш дип уйлый, әмма шушы сәясәткә каршы чыгу юлларын да белми. Эчтән көеп йөрүдән башка чарасы юк иде...

Зәйнетдин әкә сөйләгәндә, Вәлкәй хаҗидан башланган уй аны бөтенләй ерак алып кереп китте, ул оныта язган икән — алга күз ташласа, егылып китә язды, анда инде Вәлкәй хаҗи юк иде. Ике куштаны белән, әллә тагын, җир убылып, аска төшеп киткәннәр, эзләре суынып өлгергән бугай инде. Халык, бер дә исе китмәгән сыман, һаман Зәйнетдин әкәне тыңлый, мулла килеп бер авыз сүз әйтмәсә дә, шушы дәшмәве, кинәт урыныннан торып, мәҗлесне ташлап китеп баруы белән үк нинең ни икәнен төшендереп куйды инде, хәзер нәрсә сөйләсәгез, шуны тыңлыйбыз, диләр микән?.. Вәлкәй хаҗиның җыенда калган теге табак битле куштаны гына, һаман егеттән күзен алмый, балкып утыра иде. Егет хәлнең бик үк гади булмавын төшенгән иде. Эчен янә нидер яндырып үтте...

Әхмәтсафага сүз бирелгәч, ул, тез буыннары калтыравын басарга омтылып, бар осталыгын җыеп, сүзен башлады.

— Диһканнар,— диде ул, тыныч булырга тырышып,— сүз дә юк, бүген сөйләштек тә барысы да хәл ителде дип булмый. Күп өлкәләрдә колхозлар төзелә, совхозлар тернәкләнеп килә. Хәбәрләргә караганда, халык мәнфәгатен искә алып эшләгәндә, диһканнар хуплыйлар мондый үзгәрешне. Яңа тормыш төзибез, дибез икән, искечә яшәп булмый инде. Һәрьяклап үзгәрергә тиеш булабыз. Дөньясы үзгәрде, дәвер башка. Уртак Ленин бу хакта бер генә мәртәбә әйтмәгәндер, бердәм булсак кына, дөрес юлдан тайпылмасак кына хәерчелектән котылырбыз, мул тормышта яши башларбыз, ди ул. Инде сез совет хөкүмәтенең диһканнар өчен кайбер яхшылыклар эшләгәнен күрдегез. Соңгы елларда яңа икътисадый сәясәт үткәрелеп, мамыкны, каракүлне иреклe бәяләр белән сатарга хокук алдыгыз.

— Халык тәмам бөлеп, эштән чыккач,— дип, нәфрәтле сүз ыргытты арадан берәү.

— Кызганыч, сез хак әйтәсез... Хәзер хәлне төзәтү өчен чаралар күрелә. Дөрес юлга тизрәк бассак иде...

— Дөрес юл кайда соң ул? — диде теге табак чырайлы адәм.— Кая алып барып чыгармакчы буласыз халыкны?

— Нәкъ бая әйтелгәнчә,— дип, тавышын күтәрә төште Әхмәтсафа,— диһканнарны бөлдерә торган сәясәт ялгыш, аларның тормышын яхшы якка үзгәртә торган сәясәтне дөрес юл дип табам. Иң элек, үзегез уйлашыгыз, сезнең өчен кайсы юл әйбәт: һаман шулай аерым-аерым чыкмакчы буласызмы бөлгенлектән, әллә бергәләшеп чыгарга ният кылсагыз, отарсызмы? Илдә берләшү шәкеле өскә чыкты. Мәркәз күмәк тормыш корып эшләүчеләргә ярдәм кулы сузарга әзер. Аерым тормыш алып барган диһканнарга инде уйларга туры килер, бар кешегә дә ярдәм итеп бетереп булмас...

— Ленин бит алай димәгән! — дип калкына төште тәү башлап сүзгә кушылган диһкан.— Барлык кешеләрне тигез күрәбез, һәммәсе дус, туган, дигән. Ә сез ни сөйлисез? Берләшсәгез, ярдәм итәрбез, аерым калсагыз, мәйлең, үзегезне үзегез карагыз димәктә сүз алып барасыз. Дөресме бу? Юк, дөрес имәс!

— Мин сезгә бу мәсьәләгә карата мәркәз сәясәтен җиткердем,— диде Әхмәтсафа.

Сүз көрәштерүнең үз файдасына түгелен белә иде инде ул. Бу хакта чыгыш ясый башласа, һәммә җирдә шундый бәхәс куба. Сорауларга бертөрле генә җавапны бирү һич мөмкин түгел. Мәҗбүриләп халыкны оҗмахка өстерәп кертмәкче була фирка. Тик һәр кылган гамәле халыкка каршы килеп чыга. Моны мәркәздәгеләр дә сизә, башкалар да җүләр түгел, шуңа күрә туры сорауларга туры җавап бирә башласаң, җавабыңда үзең үк бутала башларга мөмкин. Жы-

енга килгән кешеләр арасында күпчелек соңгы еллардагы тәртипсез талау сәясәтеннән зур зыяннар күргән диһканнар инде бу кадәр хәерчелектән, бөлгенлектән аерым-аерым чыга алуларына ышанычын югалтып бетереп баралар. Әхмәтсафа ашыкмый гына берләшү файдасына дәлилләр китерә башлады, аларны мисаллар белән оста итеп ныгытып та куя.

Халык тынычлана төште, арада аның сүзләрен хуплаучылар да табылды кебек, ахырда, мәсьәләне өйрәнеп, алдын, артын исәпкә алып, күмәкләшү эшен башларга дигән карар чыгарып, мәҗлесне тараттылар. Зәйнетдин әкә, озакка сузмый якын көннәрдә эшкә тотынырбыз дип, вәгъдә дә бирде халык алдында. Җыен таралып беткәндә, чалмалы табак битле адәм, Әхмәтсафа янына килеп, аның белән ачылып сөйләшә башлады, Хива хәлләрен төпченеп маташты. Урамга кадәр аңа тагылып чыкты. Сүз уңаенда гына:

— Юлдаш Дәүләтъяров, шундый зур җирдән вәкил килүенә без бик шатмыз. Сөйләшәсе, киңәшәсе сүзләр күп җыелган. Бүген сезнең ниятләр ничек? — дип, егетнең күзенә карап тора башлады. — Бәлки, кичкырын янә гәпәреп алырбыз.

— Ай-һай, вакыт табып булыр микән?..

Әхмәтсафа инде үзен кулга алган, салкын акыл белән эш итә башлаган иде. Бу сорау юкка гына бирелмәгәнен дә белә, берни булмагандай, Зәйнетдин әкәгә төбәлде:

— Бераз кышлакта ял итеп алам да,— диде ул, чын күңелдән сөйләгән кыяфәт белән,— кичкә табан минә Зәйнетдин әкә белән күрше кышлакка барып кайтырга исәп.

Зәйнетдин әкә вәкилнең әле тагын бер кышлакка барырга ниятләвен белеп алгач, аны ашыктыра-кабаландыра, чәйханәдә генә калдырмыйча, үзләренә чәй уртларга алып китте. Вәкилнең күрше кышлакка барасы килүен алдан әйтеп куймавына кәефе кырылса да, үзенә сиздермәскә тырышты.

Юлга чыкканчы, дөрестән дә бераз ял итеп алырга кирәк шул, бу ашыктыруны һәркем, шул исәптән табак битле адәм дә аңлый иде. Өч сәгатьләп ял иткәч, юлга кузгалачакларын да белгәч, кош тоткандай китте вәкил белән Зәйнетдин әкә яныннан.

Кызыл комлы тар урамнан барганда да, балчык дувалкойма белән әйләндереп алынган ихатага килеп кергәч тә, җәйге йортта чәй эчкәндә дә, Әхмәтсафа үзенең уй-нияте белән хуҗаны таныштырырга ашыкмады. Тыштан сабыр булырга тырыша тырышуын, ләкин йөрәге урыныннан купкан, аңа кышлакта бер генә сәгатькә дә калырга ярамаганлыгы көн кебек ачык. Ашыгырга кирәк. Әйе, Вәлкәй хаҗи юкка гына мәҗлесне ташлап китмәгәндер. Табак битле куштаны да вәкилнең уй-ниятләре белән тикмәгә кызыксынма-

ды. Вәлкәй хаҗи, егетне тануын белдереп, керфек тә кагып азапланмады, әмма Әхмәтсафа сизеп торды — авылдашы аны таныды... Тик Вәлкәй хаҗи хакында ул Зәйнетдин әкәгә бер сүз дә дәшмәүне хуп күрде. Иң яхшысы, Дүрткүлгә кайткач, андагы җаваплы кешеләр белән киңәш-табыш итәргә кирәк. Каян килеп чыккан ул монда, ни өчен Зәйнетдин әкә, инде үтенә тиеп бетсә дә, түзеп тора аңа? Куштаннары кемнәр? Кыскасы, сораулар күп иде. Зәйнетдин әкәгә әйтсә, сүз иярә сүз чыгып, ул бу хакта тагын кемгәдер ычкындырса, Вәлкәй хаҗи эзен тиз югалтыр. Әхмәтсафаны ул танып алды, ә менә егет аны таныды микән? Бу хакта Вәлкәй анык белеп бетерми, таныдымы-юкмы? дип баш ватадыр. Шиксез, куштаны алып килгән хәбәр җирлегендә нәрсә дә булса эш кылмакчы була торгандыр. Әхмәтсафага карата берәр явызлык кылмаса, Вәлкәй хаҗи була ди ул, тот капчыгыңны, кем әйтмешли.

Чәй эчеп бетергәч, дога кылып, Әхмәтсафа аты бәйләп куелган кирттә янына килде, атның муеннарын сыйпап, аны юмалап алды. Ат ашаган, эчкән, ял иткән иде. Әлегә эшләр ул уйлаганча бара, артык яшереп азапланасы юк. Әхмәтсафа:

— Рәхмәт яусын, Зәйнетдин әкә. Мондагы хәл-әхвәлне белдем, диһканнарның холык-халәте һич тә берләшүгә каршы түгел икән. Кайбер оештыру чаралары күрәсе, аңлату эшләрен юлга саласы бар. Боларны белү миңа да, фирканең округ комитетына да бик мөһим иде. Кайтышлый Дүрткүлгә дә кереп, фикерләрне җиткереп чыгармын,— диде.

Вәкилнең болай кисәк кенә саубуллашкан сыман сөйләнүенә Зәйнетдин әкә аптырап калды.

— Чәй уртлагач, уртак Дәүләтъяров, ял итеп алыйк, әле кояшның рәхимсез чагы. Аннан күрше кышлакка озатып куярмын, боерган булса.

— Хәзер үк юлга чыгам,— диде Әхмәтсафа, хуҗаны шаккатырып.— Озатып мәшәкатьләнмәгез, юлны беләм. Миңа тоткарланырга һич тә ярамый,— дип, атының тезгенен чишеп, аны капка ягына әйдәкләде.— Бахбайны да әйбәтләп ял иттергәнсез. Рәхмәтләр яусын үзегезгә, үз игелегегез үзегезгә кайтсын...— Якын итеп, Зәйнетдин әкәгә саубуллашырга ике кулын сузды.

— Һай, уртак Дәүләтъяров, яхшы имәс, яхшы имәс,— дип, икеләнә төшеп кенә кулын бирде Зәйнетдин әкә.— Бер сүз гәпәреп, икенчесен эшлиләрме инде? Булмаганны...— диде ул һаман ризалашмый.— Күршеләргә икәүләп барабыз, диденң ич...

— Без шундый заманда яшибез шул, Зәйнетдин әкә. Иртән әйткән кичкә ярамый.

— Мәйлең инде, уртак Дәүләтъяров. Юлда уңга-сулга карап барыгыз. Сезнең сыман ялгыз юлчыга кем очрамас та, кем ни кылмас, — дип, борчылган кыяфәттә, Зәйнетдин әкә Әхмәтсафаны озатып калды.

Кышлакны чыккач та, егет атын күрше кышлак ягына түгел, кире якка, ягъни килгән юлга борды. Юл дисәң, хәтерең калыр, бу якларның холык-фигыле шул, әле ике-өч сәгать элек үткән эзне ком күмә дә китә. Бәхеткә каршы, Каштаудан Дүрткүлгә алып кайтучы юл шактый өметле икән, эзләр дә сакланган, аннан бу якларда йөреп өйрәнгән атларның табигате шундый, алар кайту ягын искәреп алсалар, юнәлешне тиз тотып алалар, эз булмаса да, юлны саташтырмый, җайдакны исән-имин алып кайтып җиткерәләр. Әхмәтсафа шуңа исәп тота да инде.

Егет атын мөмкин кадәр куарга тырышты. Әмма чаманы да югалтмаска кирәк, атың янып эштән чыкса, үлем белән бер. Юлда кое фәлән очрамады, көмештәй елтырап яткан елгага кадәр дә ерак. Аның уйлавынча, Вәлкәй хаҗиның ниятендә егеткә каршы яманлык кылу булса, ул аны, һичшиксез, күрше кышлакка барганда яки аннан кайткан чакта эшләргә хәзерләнәдер. Әгәр кышлакта куна калса, аннан исән-имин чыгу икеле иде. Вәлкәй хаҗиныкылар Әхмәтсафага яманлык кылып кына калмаслар, Зәйнетдин әкәнең ишле гаиләсе дә каза күрүе бар. Һич булмаса, атына зыян салачаклар иде алар. Вәлкәй хаҗиның ат караклары белән бәйләнештә торуы хакында сөйлиләр иде авылда. Ышанганы ышанды, ышанмаганы юк, әмма әткәсе Мостафа, Вәлкәй хаҗи турында сүз чыкса, теш арасыннан гына: «Ат буры!» — дип ычкындыргалый иде. Димәк, Әхмәтсафа Каштауда төн үткәрә алмый, юлга чыгуы һәрьяктан аклана. Чүл буйлап дулап чапкан атының муенына ята төшеп, егет шуларны уйлап алды. Ярты сәгать чамасы вакыт үтте, артта шикле нәрсә күрмәде, тоймады ул. Курыкканга куш, икесе бергә биш, юкка шыр җибәрде бугай ла...

Атын тыя төште, тәмам тынычланып килгәндә, артка борылып караган иде, йөрәге жу итеп китте, үзен куып томырылып чабып килүче ике җайдакны шәйләп алды. Ат өстендә кемнәр икәнен чамалавы кыен, әмма аларның Хивадан килгән вәкилне куа чыгучылар икәнлегенә дә шик юк. Аңлашыла. Шулай булмаса, эссе кояш астында шулкадәрле ашыгырлык ни эш бар? Әхмәтсафаның аты да төшеп калган түгел, шактый элдереп өлгерде кышлактан чыккач. Димәк, аны куалар... Егет, үзенең ялгышмавын аңлап, атының касыгына үкчәсе белән нык кына төртеп алды. Туры айгыр алга омтылды... Арттан куучы җайдакларның (инде алар аермачык күренә башлады) атлары шәбрәк, елдамрак иде, ахрысы,

ара торган саен якыная бара. Әхмәтсафа, өйдә онытылып калган револьверын исенә төшереп, ачынып, сызланып ыңгырашкандай итте. «Их!..» дигән әрнүле тавыштан хәтта ат та, тигезлеген югалтып, бермәл чабу эзенә төшә алмый азапланды кебек. Аны коткарса, бер генә нәрсә коткара ала — калкулыкка менеп, сөзәк араны үткәч, тау төшәсе, аннан елгага килеп чыгасың, теге ярда исә чаукалык, агачлар, таллар, чытырманлык... Шунда качып калса гына инде. Аермачык ишетелә, җайдаклар әллә һавага, әллә үзенә төбәп шарт-шорт мылтыктан ата башладылар. Ара ерак калмый, димәк. Әмма артка борылып карарга форсат юк. Куркудан бөтен тәне калтыраган шикелле тоела, ул, үз-үзен белештерми, атына кычкыра, аны куалый башлады.

Калкулыкка менеп, бераз чапкач, еракта елтырап яткан елга күренде. Егетнең күңелендә өмет канат җәя, аты да аны аңлый кебек, тагын да ашкынып җилдерә башлады. «Әйдә, бахбай, әйдә!» Егет күңеленнән генә дәшкән сыман булса да, шактый кычкырып әйтә иде бугай сүзләрне, ат соңгы көченә җитеп чаба иде инде елгага табан. Арттагыларга борылып та карамый Әхмәтсафа, ике-өч пуля колак яныннан гына сызгырып үтте. «Әйе, каптың, егет, Вәлкәй хаҗиның кара тозагына!» — дип ачынып уйлап кына алды. Күрше кышлак хакында сөйләнгән булып, эзне саташтырып, үзенә күрә тапкырлык күрсәтеп маташмаса, эш ни белән беткән булыр иде? Кем кемне?! Сизенүе дөрес булган, әгәр Зәйнетдин әкәдә чәйләп тормаса, бәлки, бу тозакка эләгеп тә азапланмас иде. Эш узгач кына акыллы булып кыланасың шул. Терсәк якында... Хәер, кая монда терсәк кайгысы!

Елгага килеп тә җиттеләр. Аты суга очып кына килеп төште кебек. Ат аяклары астында су кайный сыман, егетнең өстенә су тамчылары бөркелә, тагын дүрт-биш ыргым һәм ул инде агачлар арасына кереп китә ала. Баш очында зәһәр чыелдап пулялар оча. «Әйдә, бахбай, әйдә!» — дип шашынып пышылдый Әхмәтсафа. Көтмәгәндә аты нәрсәгәдер абынды, кисәк башын суга чумдырып алган сыман итте. Су эчәргә маташа түгелме соң бу хәерсез. Шундый мизгелдә, инде котылдым дигәндә, атның шулай баш бирми маташуына җен ачуы чыгып, атының касыгына типте. Кара туры тагын бер ыргым ясады, аннан тизлеген югалтып, сәер урхылдап, башын янә суга чумдырды. Егет кычкыра, атын һаман куалый, ат исә хуҗасын ишетмәгән дә кебек бөтенләй туктап калды, буыннары йомшарып, шаулап аккан суга гөрс итеп чүкте дә агым уртасына сузылып ук ятты. Әхмәтсафа, тезгенен ычкындырмаган килеш, суга барып төшкән мәлдә, аякка басып, атын тарткалап маташканда, атның сырты буйлап ургылып-ургылып аккан канны күреп, үрсәләнеп кычкырып җибәрде:

— Бәдбәхетләр, атка... атка төзәп аттылар бит!..

Куа килүчеләр дә елгага атылып килеп керделәр. Әхмәтсафа, нишләгәнен белмичә, атының муенына ташланды, җаны чыгып бетмәгән малкайны кысып кочаклады да күзен йомды. Тозактан ычкынып булмасын аңлаган иде инде ул.

...Егетнең баш өстендә пулялар яңгыры... Ниндидер могҗиза аркасында аңа әлегә берсе дә тими. Тереләй алмакчылар, күрәсең... Куып килгән җайдаклар килеп җитеп, аның эшен бетерер вакыт үтте, һаман ату, ниндидер сәер тавышлар. «Шашыналар, бәдбәхетләр, бәйрәм итәләр үзләренчә. Вәлкәй өскә чыкты, сөенерлеге бар. Их, револьвер булса...» Шулай уйлап бетермәде, баш очында гына яңгыраган тавышка сискәнеп, ирексездән аяк өстенә басты. Тавыш исә таныш, һич тә ачулы түгел иде:

— Әхмәтсафа, син исәнме?

Билдән суда килеш шәлперәеп торган егет, ат өстендәге җайдакка күтәрелеп карагач, имәнеп китте, үз итеп, шул ук вакытта җитди дә тавыш белән хәлен сорашучы кеше — Фәтхулла иде... Егетнең исән-имин икәнлегенә инанып, бары тик әлеге мәхшәрдән һушын җыя алмый торганын абайлап, Фәтхулла ике уйлап тормый суга, Әхмәтсафа янына ук сикереп төште.

— Ярый әле, өлгердек, беткән идең, парин,— диде ул һәм, егетне тизрәк һушка китерергә тырышып, җилкәсенә үз итеп кулын салды.— Тәки өлгердек...

— Атны үтерделәр...

Әхмәтсафа һаман Фәтхулладан башка кешене күрми, үзен кемнәр куып килгәнен белергә теләп, артка борылып карарга да җөрьәт итми.

Яннарына су чәчрәтә-чәчрәтә янә бер җайдак чаптырып килде.

— Берсе яраланган, берсен дөмектердек, уртак Галиев.— Фәтхуллага дәшүе иде аның.

— Яралысына беренче ярдәм күрсәтегез, ничек тә исән-имин сакларга тырышыгыз анысын. Кайбер нәрсәләр хакында сорашасым бар, хәзер килеп җитәм.

— Каштауда Вәлкәй хаҗины күрдем. Миңа һөҗүмне ул оештырды булса кирәк,— диде Әхмәтсафа, ниһаять, һуш җыеп.— Сизенгән идем, үзенә күрә хәйлә дә корып маташтым, барыбер арттан куып тоттылар.

— Кышлактан чыгасың калмаган. Килеп җитә идек бит.

— Кем белгән бит...— диде Әхмәтсафа. Суда яткан туры айгырның үле гәүдәсенә карап, үкенгән тавыш белән өстәп куйды.— Аттан яздым менә. Кызганыч малкай.

— Үзең исән калгансың, шуңа сөен. Шулай итеп, Вәлкәй

хаҗины күрдем, дисең инде Каштауда. Ялгышмадыңмы? Сөйләштегезме?.. Ниләр сайрый чалмалы кош?

— Анда, мине күргәч, сайрау кайгысы булмады бугай. Танымаган сыман кыланды. Сизми калдым, җыен барган җирдән чыгып киткән. Шулай сәер генә юкка чыккач, күрше кышлакка, бөтенләй кире якка барам дип, үземчә эзне саташтырып, Дүрткүлгә киттем кайтып. Күрәсең, алар мине башта кышлакка бару юлында көтеп торганнар инде. Аннан хәбәр килеп, арттан куып, эзгә бастылар. Ә сез ничек? Монда каян килеп чыктыгыз соң әле? — дип, каударланып Фәтхулладан сораша башлады.— Йомышыгыз төштеме бу якларда? Хәер, эшегез булмаса...

— Кичә төнлә кизүдән кайтып керсәм, Шәмсия әнкәң елардай булып утыра. «Күңелем сизә, бер-бер хәл булмасын Әхмәтсафага. Черем итеп алганыем, әллә нинди төшләр күреп бетердем»,— ди. Кыскасы, миңа йокы бирмәде, үземне дә эчтән корт кимерә, коралсыз-нисез чыгып киткәнеңне белгәч, тәмам тынгы бетте, иртүк егетләрне алдым да каршыңа киттем. Хатын-кыз күңеле сизә бит ул. Тап өстенә баскан. Гаҗәп инде, чирек чакрым юл үтәрлек вакыт соңга калсак, ни булыр иде, ә, егет?!

— Ни булсын, «чүкеп» китәрләр иде инде.

Алар, сөйләшә-сөйләшә, яралы эзбасар янына килделәр. Ярдагы чирәм өстендә аһ-уһ килеп шыңшып яткан табак битле таныш йөзне күреп, Әхмәтсафаның шыбыр су аркасына кайнар тир бәреп чыкты. Табак битле адәм, ярасы авыртуын онытып, ачу белән Әхмәтсафага карап торды да:

— Исән икәнсең, нугай баласы. Газраилең без имәс, без — кушканны үтәүче генә,—диде һәм, авыртуга түзә алмыйча, ыңгырашып, күзләрен йомды.

...Фәтхулла Хивага ике көннән соң гына кайтып керде. Арып-талчыккан йөзенә карап, ниндидер мөһим эш башкарып чыкканын аңлап алдылар өйдәгеләр. Хәер, ашап-эчкәч, йорт хуҗасы үзе дә ялындырып тормады, шушы ике көндә күргәннәрен сөйләп бирде. Башка вакытта үзенең эше хакында өйдәгеләргә ләм-мим дәшми йөргән Фәтхулланың кинәт сүзчәнләнеп китүенә Шәмсия исе китеп утырды.

Каштауга Фәтхулла төркеме кергәндә, Вәлкәй хаҗиның эзе әллә кайчан суынган булган инде. Әмма яралы эзбасардан хаҗиның һәм яраннарының алдан әзерләнгән яшерен урыннарын әйттерә алганнар. Әйтмәсә, ярдәмсез-нисез үләсен белгәч, барысын да сөйләп биргән ул. Иске кое дигән җирдә, чабаннардан калган куышта тотып алганнар Вәлкәй хаҗины. Өсләренә милиция килер дип башларына да китермәгәннәр, Әхмәтсафаның җанын кыярга киткән ике эзба-

сарны көтеп ятулары икән. Коралсыз-нисез бер малайны юк итүне эшкә дә санамаганнар инде алар. И өтәләнгән Вәлкәй хаҗи килеп эләккәч, и өзгәләнгән. Гөнаһсыз сабый сыман, әүлия шикелле тоткан үзен. Тикшерүчегә барысы да билгеле икәнен, хөкемгә тартылудан котыла алмаячагын төшенгәч, чөнки Әнвәр паша оештырган гаскәрләр сафында сугышып йөрергә дә өлгергән икән, ул чакта кылган явызлыклары да фаш ителгәч, Фәтхулла белән очраштыруларын үтенгән.

— Тикшерүче янында очраштык,— диде уйчан гына Фәтхулла абзый.— Бернәрсәне дә онытмыйм, төшереп калдырмыйм дигәндәй, Вәлкәй хаҗи ашыгып-кабаланып сөйләп бирде. Шәмсия сиңа китергән золымнарын да әйтте, иң аянычлысы шул, моны Әхмәтсафага әйтәсе дә килми, белсә, яхшырак булыр, әткәсе Мостафаны, үч алу нияте белән, Вәлкәй хаҗи үтерткән икән. Каргалы очындагы Абдулла белән бер шәкертен котырткан... Иртән лапаска килеп керүгә, «эһ» тә итә алмый калган, элмәк салынган муенына... Синең исән калуыңны белгәч, әшәке итеп сүгенде, ис-акылларым китте, гомере буе дин дип авыз суын корыткан адәм Ходайга яман сүз тигерде. Ышан син аңа...

...Берничә көннән Әхмәтсафа, округ комитетында эшен тапшырып, Каргалыга юл тотты. Хивадан аны якын кешеләре — Фәтхулла абзый, Шәмсия әнкәсе һәм сеңлесе Бибкәй озатып калдылар. Хивада үткән гомерен ул файдасыз, әрәмгә үтте дип әйтә алмый. Шулай да күңелендә авыр истәлекләр генә калдырды бу яклар. Әткәсе язмышы хакында уйлап, ул бернәрсә төшенде, кешегә игелек күрсәтеп, аннан рәхмәт өмет итү, аянычка каршы, бу дөньяда иң зур тилелек бугай...

## IV

Минзәләгә, кичке караңгылык иңгәч, соң гына килеп керделәр. Бөтен шәһәрне кар күмеп киткән кебек. Тәрәзәләрдән төшкән сүрән ут яктысында оеп кына утырган шәһәр. Әхмәтсафа, соңга калуларына пошынып, шулай да шаяра төшеп, ямчы агайдан:

— Мине кайда бушатасыз инде? — дип сораган булды.

Ямчы агай байтак барды өлкәдән килгән вәкилгә җавап кайтармый, шуннан соң гына исе китмәгән төслерәк җавап бирде:

— Минзәләгә кадәр исән-имин китереп җиткергәч, бушатыр урынын табарбыз анысы. Монау килеп тә җиттек, кем, вәкил иптәш,— дип, чаттан борылып, шактый яктырып утырган ике катлы бина алдына китереп туктатты атын.— Башлыклар, хуҗалар, түрәләр — барысы да шушында җы-

елып ята инде. Төне буе йокламыйлар, көне буе тынгылык юк — кая карама алар, әле җыелыш, әле таралыш. Ничек чыдый торганнардыр. Бернәрсәне авызларына алсалар, чәйниләр дә чәйниләр, ачуым килмәгәе, чүбек чәйнәп, май чыкмый, диләр, болар чыгара, туган, әллә нәрсәләр чыгара... Син, вәкил иптәш, аякларыңны яза тор, мин, кизүгә кереп, «йөк»не исән-имин алып кайтканга язу алып чыгыйм, аннан, боерган булса, кәнүшнигә атны туарырбыз да җәяүләп Иркәнәшкә теркелдәрбез, әйе бит, бахбай,— дип сөйләнә-сөйләнә, кантком бинасына кереп китте.

Озак та үтмәде, ишектән йөгерә-атлап чыгып килүче милиция киемендәге кеше күренде. Ул чыга-чыгышка Әхмәтсафага эндәште:

— Иптәш Дәүләтъяровмы?..

Күшеккән иреннәрен җиңелчәрәк кыймылдатырга тырышып, җавап кайтарды:

— Үзе булам, Казаннан...

Милиционер, күп сүз куертып тору кирәкмәс дигәндәй, юлчыны ашыктыра башлады:

— Иптәш Филиппов белән иптәш Солтанов волком җитәкчеләре белән киңәшмә үткәрәләр, сезгә иптәш Мусин бүлмәсенә керә торырга куштылар.

Югарыда телгә алынган баштагы ике кешенең кантонда фирканең җаваплы сәркатибе һәм башкарма комитет рәисе, Мусинның агитация-пропаганда бүлеге мөдире икәнен Әхмәтсафа белә иде инде.

Мусин — эре сөякле, талчыккан йөзле кеше, Әхмәтсафа килеп керүгә, түрдәге өстәл артыннан авыр гына күтәрелеп, аңа каршы чыкты, күрешергә кулларын сузды:

— Иптәш Дәүләтъяров?.. Юлга чыгып китүегез турында хәбәр иткәннәр иде инде. Егермебишмеңче, значиться? Ноябрь пленумы карарларын безнең белән бергәләп тормышка ашырабыз дисез инде?

— Шулай булып чыга, ахры. Чанада Чаллыдан биреп җибәргән китаплар, плакаты, башкасы бар, бушатасы иде бит.

— Шәп, шәп. Безгә китапны олавы белән ташысаң да, артык булмас.— Мусин зарланган сыман өстәп куйды.— Караңгы яклар бит, иптәш Дәүләтъяров. Бүлектә ике-өч кеше элекке бөтен бер өязне агартып яткан булабыз. Ничек өлгермәк кирәк? Шуңа күрә Казаннан егермебишмеңче килә диюгә, җитмәсә, ТКУда белем җыйган кеше, Филипповка ультиматум куйдым: «Миңа бирәсез!» — дидем. Мин бит ике сөйләшмим, дәвер шулай куша. Иптәш Филиппов янына башка бүлекләрдән дә кереп чыш-пыш килеп йөрүчеләр булды, ну минем холыкны беләләр, күп сөйләшкән кешенең муенына уч кырые белән генә тартам. Кылычтан ким түгел.

Хе-хе... Кәк же, гражданнар сугышында илне кылыч белән аркылыга-буйга айкап чыккан кеше бит мин! Әле кичәге киңәшмәдә Филиппов: «Вәкил юлга чыккан»,— дип әйтүгә, боргалана башлаганнар иде, урындыкка кадаклап кына куйды теге кыбырсыкларны. Филиппов күзен алартып бер карады да: «Мусин, синең бүлеккә килә яңа иптәш»,— дип ярып салды. Менә шулай, значиться, иптәш Дәүләтъяров. Кадрлар җитми, халык арасында агарту эшен тиешле югарылыкка куясы бар. Менә хәбәрләр йөри, имеш, Чаллыны шәһәр итеп, үз башка аерып чыгарасы икәннәр. Ишетмәдеңме андый хәбәр? — Әхмәтсафа, юк дигәнне белдереп, башын чайкап куйды.— Итсеннәр, сүзем юк,— диде Мусин, вәкарь белән генә,— ичмасам, файдасы булмасмы бераз...

...Минзәләгә китәр алдыннан үзе сыман егермебишмеңчеләрне Разумов, өлкә комитетына чакырып, озак кына коллективлаштыруның әһәмияте, коллектив хуҗалыклар төзүгә аяк чалучы корткыч-дошманнар турында сөйләгән иде. Залда утырган районнарга китәргә тиешле дүрт йөз егермебишмеңченең һәркайсының аңына сеңдерерлек итеп әйтте:

— Авылларда колхоз төзү эшенә аяк чалучы бер генә кулак та, аларның ялчылары да калырга тиеш түгел. Аларны шау-шусыз тиз арада җыеп алырга, тиешле урыннарга озатырга. Бүгенге көндә совет хөкүмәтенә каршы нәсыйхәт үзәгенә әверелгән мәчетләрне ябарга, бу эшкә каршы муллаларны, аеруча диндар мәчет картларын барлап, колхозга өндәргә, игә килмәсәләр, шулай ук ГПУ кулына тапшырырга. Церемониться не будем! Яңа 1930 елның язгы чәчүен йөз процент коллектив хуҗалык булып каршы алырга тиеш авыл. Бу — партия куйган таләп һәм без аны, ышанам, сезнең ярдәм белән, һичшиксез, үтәп чыгарбыз!

Әхмәтсафаның мондый зур түрә белән беренче мәртәбә очрашуы булмаса да, үзендә ниндидер гайре җаваплылык сизеп, аның һәр сүзен хәтеренә сеңдерергә тырышты. Аннан Разумов өлкә комитетында, Казанда зыялылар арасында булып алган уң һәм сул тайпылышлар, түрәләр арасында төркемчелекнең һич тә тамырдан ук бетерелмәве, мондый чатаклыклар юк-юк та үзен сиздереп куюы, аеруча кантоннарда төркемчелек вируслары оста яшеренеп, сакланып калуы хакында нотык тотты.

— Солтангалиев сабагын тиз онытты татарлар! — дип сөрән салды ул, залдагыларның аркалары чымырдарлык ачы тавыш белән.— Солтангалиевне, аның гарип идеяләрен юкюк та күтәреп чыгучылар табыла. Уйлап кына карагыз, утызынчы елга кереп барабыз, һаман бер балык башы чәйнибез. Никадәр тирән кереп калган солтангалиевчелек кайбер тинтәк башларның аңнарына.— Разумов көтмәгәндә Татар ком-

мунистик университетына ябышты.— Мин аеруча ТКУдан килгән иптәшләргә мөрәҗәгать итәм: «Җитте!» — дим. ТКУ ректоры Вольфовичның үзенә, студентларына соңгы кисәтү!

Егермебишмеңчеләр алдында Татарстан АССР халык комиссарлары советы рәисе Кәримулла Исмаев, ноябрь пленумыннан соң җир эшләре халык комиссары итеп сайланган Габдрахман Искәндәров һәм ТАССР Үзәк башкарма комитеты рәисе Байчурин чыгыш ясады.

Гомәр Байчурин чыгышын Әхмәтсафа аеруча игътибар белән тыңлады. Байчурин берничә ел Минзәлә кантонында эшләгән. Андагы уң тайпылышларга каршы оештырган көрәше хакында озаклап сөйләде. Бигрәк тә егерменче елларда Минзәлә кантонында эшләп киткән Миңгәрәй Сәгыйдуллинга каты эләкте. Ул чәчеп калдырган «солтангалиевчелек орлыклары», милләтчелек тәгълиматы белән көрәшүнең никадәр авыр һәм мәшәкатьле булуы, шулай да кантонда сәгыйдуллинчылыкның бер генә шөребе, винтигы да калмавын искәртеп, инде Минзәләдә тамырланган бухаринчылыкны бетерү кирәклегенә басым ясады. Болар турыдан-туры Әхмәтсафа Дәүләтъяровка төбәп әйтелгән сыман яңгырады ул чакта. Менә хәзер ул Минзәләдә, Разумов әйткәнчә, үз-үзенә галәмәт ышанган тәкәббер татар түрәсе каршында тора.

Мусин бүлмәсендә салкынча иде. Әхмәтсафа, кергән уңайга, кызуланып, өстендәге озын шинелен салып куйган иде, аны кире иңбашына элде һәм, әңгәмәдәшенең аңа урын тәкъдим иткәнен дә көтмәстән, күн аркалы урындыкка утырды. Арылган, берничә көн юлда булу тәмам йончыткан иде.

— Хәзер инде озаклап сөйләшергә вакыт та юк,— диде Мусин, урыныннан күтәрелә башлап.— Киңәшмәгә кереп тормассыз, мин иптәш Филипповка тиешенчә җиткерермен.— Ул, елмая төшеп, Әхмәтсафага өлкә комитетыннан биргән юлламаны кулында әйләндерде.— Юлламаны алып калам, хәзер сине кизү бүлегеннән берәр милиционер фатирга илтеп куяр. Иртән, иртүк килеп җитегез. Безнең монда төн-көн юк. Ноябрь пленумы карарларын үтәү, ай-һай, җиңел бирелми. Инде, нигездә, бөтен волостьлар колхоз төзү турында рапорт бирәләр. Әмма кулаклар аяк чала-а!..— дип сузды ул, әрнү белән.— Һич акылга китереп булмый үзләрен. Бүгенге көндә авылларны кулаклардан чистарту бара. Мулла-мәзиннәрне җыябыз. Мәчет картлары белән Минзәлә төрмәсе тулды. Ә күпме авылга кул да тимәгән әле?! Иртәгә сине ерактагы авылларның берсенә — Әмәкәйгә җибәрәм. Зур авыл, базарлы-ярминкәле авыл. Үҗәт халык яши. Борынгыдан волость үзәге булгач, теләсә нинди килмешәк килеп тулган. Сәүдәгәрләрен, кулак, муллаларын җыеп алып

кайтабыз. Син вәкил булып барасың. Борчылма, Әмәкәйдә ышанычлы иптәшләр эшли, әллә кайчан исемлек төзеп куйганнар. «Кайчан җыеп алып китәсез!» — дип, бәгырьгә төштеләр инде. ГПУдан кешеләр бара. Олаулар белән авыл үзе тәэмин итә. Анысы да хәл ителгән дип хәбәр итәләр. Утызлап кешене төрмәгә китереп ябасы була. Аларны исән-имин китереп җиткерү синең җаваплылыкта!

Әхмәтсафаның йөзе бозылды. Моны Мусин да күреп алды, вәкил иптәшне тынычландырырга ашыкты:

— Аңлыйм, аңлыйм, иптәш Дәүләтъяров. Күңелле эш түгел. Ләкин башкача мөмкинлек юк. Авылларны кулаклардан, башка корткыч элементлардан чистартмый торып, без колхозлар төзи алмыйбыз. Төзеп карадык инде — бер генә хәлле кеше дә колхозга аяк басмый. Җыен хәерче, җирсез, суыгаяклар кереп тулды менә. Алар белән нишләп булсын? Кулак сөенә, эчтән генә көлеп йөри. Аңа колхоз нигә? Атлары шәп, җирләре әйбәт, көч бар, кирәк булса яллап та эшләтә. Әнә хәбәрләр килеп тора: бер хәерче байгыш колхозга кергән, үзе, кулакка ялланып, ашлык суга икән. «Ул күмхуҗның нәмәсе бар соң? Менә мин эшләгән фәлән абзый кебек ныгысын башта, аннан килермен күмхуҗга», — ди икән. Менә йөр син аны колхоз әгъзасы дип. Дөрестән дә, кеше түгел, әгъза гына инде ул. Бер генә юл кала — кулаклардан ашлыкны, машинаны, каралтыны тартып алып, колхоз милке итәргә.

— Ә үзләре ни эшли инде?

— Кемнәр? — дип сорады Мусин, аптырый төшеп.

— Хәлле крестьяннар диюем. Алардан башка күмәк хуҗалык төзү көлке бит. Кем эшләр колхозда?

— Бухаринчы! — диде зәһәрләнеп Мусин.— Син генә җитмәгән идең монда! Энекәш, андый уй белән килсәң, дүрт ягың кыйбла, юлыңа ак җәймә. Болай да буталып беткән башка син генә кирәк идең. Колхозда кем эшләр, дисең. Әле аны башта чынлап төзергә кирәк. Эшләүчеләр табылыр. Татар хатыны ике елга өч бала таба. Җиде яшьтән кулына урак тота башлый татар баласы, утауга чыга. Беренче адымны ясау кыен, аннан майлаган коймак булачак эшләр. Кулакларны гына себереп түгик менә. Күрерсең, иптәш Дәүләтъяров, партия сүзе өскә чыгачак!

Әхмәтсафа, саксыз сүз ычкындырып, Мусинны кыздырып җибәрүен аңлап, телен тешләгән иде инде. Чак кына онытылып китте егет, ТКУда күнегелгәнчә, бәхәс урыны түгел бу.

— Мин болай гына...— диде Әхмәтсафа, Мусинның сүрелә төшүен күреп.— Сезнең фикерне белергә теләгән идем. Иң мөһиме — әңгәмәдәшнең нинди мәсләктә торуын ачык-

лау бит, сынап карау димме. Килешәм, кулакка күмәк хуҗалык кирәкми. Партия тулысынча коллективлаштыру бурычын куйган икән, ул үтәлергә тиеш, ничек булса да үтәлергә тиеш...— Ул Разумовның «тир түгеп, кан белән» дигән сүзләрен исенә төшерде. Бу эшнең никадәр авыр һәм каршылыклы булуын аңлап бетерә микән фирка җитәкчесе үзе?.. Дөнья хәлен белеп булмый, үз башыңа төшмәсә, диләр, инде үзенә турыдан-туры шушы аңлаешсыз көрәшкә кушылып китәргә язган икән. Китаптан укыган бер нәрсә, ә гамәл икенче нәрсә шул. Шулай да бераз аңлатып, сөйләп-күрсәтеп җибәрерсез инде. Болай гына чыгып китеп...

— Сөйләрбез дә, күрсәтербез дә, иптәш Дәүләтъяров. Моннан соң иптәшләрне сынап җәфаланма, без барыбыз да каткат сыналган. Бусы дусларча киңәш. Утлар-сулар кичкән иптәшләр. ТКУда укымасак та, «Минзәлә мәктәбе» диләр моны, бу мәктәпне үткән иптәшләрне Казан үзенә җыя тора. Сәгыйдуллинны да алды Казан, Байчуринны да, башкаларны да...

— Сәгыйдуллинга төрлечә карыйлар Казанда.

Мусин көчәнеп көлеп җибәрде. Инде саксыз сүзне ул ычкындырган иде.

— Бусы сине сынау өчен, дускай. Сәгыйдуллин турында болай гына сүз кузгаттым... Үҗәт кеше ул, арты белән киртә җимерергә маһир. Әйдә, киенә тор, хәзер үк кизү милиционерны чакыртам, озатып куяр фатирыңа...— дип, Мусин, ишектән башын тыгып, үтеп баручы адәмгә кычкырды: Кизүне җибәр әле монда, Хәбибуллин. Эш бар!

* * *

Юл йөрүгә күнегеп киләме, сәфәргә Әхмәтсафа авырыксынмый кузгалды. Алда нинди эшләр торганын да чамалап бетерми, Мусин белән булган кичәге сөйләшүдән әллә ни мәгънә тапмады. Яңа көн туарга өлгермәде, ул инде кантон бинасында иде. Башкарма комитет рәисе Солтанов ГПУдан әлеге эшкә җаваплы итеп билгеләнгән Шәмтиев дигән кешегә, җентекләп, Әмәкәйгә ничек барырга икәнлеген, иң беренче кемгә мөрәҗәгать итү, җыелган халыкны ничегрәк тынычландыру, кулак-муллаларын алдап-йолдап чанага төяп, авылдан чыгып таю серләрен аңлатуын тыңлап утырды. Шунда гына нindirәк эшкә килеп капканын тулысынча аңлады. Филиппов бүлмәсендә дә булып чыкты, аңа, чыннан да, Мусин кул астында эшләргә туры киләчәк. Агитация-пропаганда бүлегендә исә кулына культпроп мөдире итеп билгеләнүе хакында язу тоттырдылар.

Ат менгән гаскәриләр — ГПУ кешеләре озатуында ике

кошевка, Минзәләдән чыгып, Әби-патша күпере дип аталган дугалы тимер күперне үтеп, калын урманга килеп керделәр. Алдагы кошевкада Шәмтиев белән башкарма комитеттан кулга алынган кешеләрнең йорт-малларын конфискацияләргә тиешле хезмәткәр бара, Әхмәтсафа янына хәрби комиссариаттан нindидер йомыш белән юл өстендәге бер авылда төшеп калырга тиешле утыз яшьләр тирәсендәге ир-егет утырды. Кошевкалар да ГПУдан булып, кучерлары аркаларына винтовка аскан гаскәриләр иде.

...Озын юлда иркенләп үз уйларыңда йөзәргә җай чыга. Ык елгасын кичеп, атлар Әтрәкле дигән авылга йөз тотып юырта башлагач, Әхмәтсафа уйлар диңгезенә чумды.

...Хивадан кайтып, Каргалыда озак тормады ул. Рабига белән очрашкан-кавышкан татлы минутларны искә алмаганда, хәтердә яңартырлык тагын ни булды икән? Әйе, Рабиганың башка чарасы калмаган, әнисе белән энесен, әткәсеннән качырып диярлек, үзе белән алып килгән иде. Алдан хат язып, килешкәнчә, Атбасар качаклары вакытлыча Каргалыда, Әхмәтсафаларның өенә урнаштылар. Кызның әнисе кечкенә буйлы, бөтерчек кебек Хәлимә апай белән танышып, бер-берсен бик тә үз иттеләр. Эре сөякле үсмер Шираз — Рабиганың энесе белән дә тиз дуслаштылар алар. Шираз, һәр нәрсәдән кызык табып, кәмит ясарга һәвәс икән, аеруча кеше булып кыланырга ярата. Әхмәтсафа аңа «әртист» дигән кушамат та тагып куйган иде, Ширазга гына ошап җитмәде.

— Артист булмыйм ла мин...— диде ул, уенны чынга алып.

— Кем буласың килә? — дип сорады Әхмәтсафа, үсмернең кинәт җитдиләнеп китүен күреп.

— Кавалерист! — диде горур рәвештә күкрәген алга чыгарып Шираз.— Буденный кебек ат өстендә кылыч белән менә шулай, менә болай акларны кырасың гына...— дип, ат өстендәге кызыл җайдак кыяфәтенә кереп, ишегалдында килештереп сугыш уены да күрсәтеп алды.

Малайның минут эчендә шундый үзгәреш кичерә алуына сокланып, Әхмәтсафа кулын Ширазның шактый нык җилкәсенә салды:

— Кылыч селтәп чабардай кавалеристлар күп булыр ул, каениш. Ә менә артист һөнәре алсаң...

Рабига бер читтән аларның сөйләшкәннәрен тыңлап тора иде, «каениш» дигән сүзне ишеткәч, комачтай кызарып, тизрәк өй ягына атылды. Әле һаман бер-берсен сөйсәләр дә, вәгъдәләр бирешүдән узмый мөнәсәбәтләре. Әхмәтсафа янә Казанга укырга китәргә җыена, Рабига исә, ТИНОны тәмамлап, быел көздән Каргалыда укыта башлый. Казанда ни булып бетәр, Әхмәтсафа юлына кемнәр очрар, егетнең берәр

чибәркәйне күреп, башы әйләнеп китмәсме?.. Уйлый башласаң... Кызның күңеле тулы шөбһә. Ул Әхмәтсафага бик тә ышана. Шулай да... Инде яше дә бара бит. Егерме яшьтән үткән кызларны «сазаган» дип үртәргә дә күп сорамыйлар аны.

Хәлимә апайның исә үз хәсрәте, үз борчуы. Карты Мөхәммәтҗан кызларының сәвит яклы булып китүен, гореф-гадәтне бозарга җөрьәт итүләрен күтәрә алмады. Сырхауга сабышты башта. Исенә килгәч, Хәлимәне җәберли башлады, түзәр әмәл калмады, ул да булмады, ир кеше яшь бичә алып кайтты. Әле бусына түзәргә буласы икән. Көндәш белән яшәү бер Хәлимәдән генә калмаган. Мөхәммәтҗан торган саен холыксызлана бара. Бигрәк тә Җамалның яланбаш йөрүенә үчекте. Кызның ирдәүкәләнеп йөрүен бары тик хатыныннан гына күреп, Хәлимәне төпчек улы Шираз белән өеннән үк куып чыгаргач, дөньялар җимерелеп төшкән кебек булды. Кешедән кешегә йөреп, тамак ялына йорт эшләрендә булышып, кайда туры килсә, шунда кунып йөргәндә, бәхетенә, Рабига кызы кайтып төште. Өйдән куып чыгарса да, Хәлимә моны аерылышу дип уйламый, ире бер акылына килеп, өйләренә кайтарып кертер дип өметләнә иде. Рабига катылык күрсәтте, икенче көнне үк, ай-ваена карамыйча, Каргалыга алып китте үзләрен. Әүвәл Оренбурда, Рабига янында тулай торакта көн күреп азапландылар. Әхмәтсафага рәхмәт, һич тә авырыксынмый өйләренә алып кайтты, Гомәрхан абыйсы белән сөйләшеп, аларны өйдәш итеп урнаштырды. Гомәрханы да ипле булды. Алар киләсе елны Оренбурда тракторчылар мәктәбендә укып, авылга беренче тракторны алып кайткан ир-егет ул! Инде яздан бирле Зариф белән колхоз төзибез дип җенләнеп йөриләр икән. Күмәкләшеп язгы чәчү үткәргәннәр менә. Игеннәре матур булып өлгереп, башаклары тулышып килә. Гомәрхан Сабан туенда өйләнеп җибәрде, хәзер үз тормышы. Һаман-һаман кеше өстендә торуы кыен бит. Бу хакта сүз кузгаткан иде, Әхмәтсафа килештереп бетермәде:

— Хәлимә апай,— диде ул, кулын йөрәге турысына куеп.— Мин бит сезгә чит-ят кеше түгел. Рабига минем булачак кәләшем. Казанга барып урнашыйм, бераз уңны-сулны карарга кирәк, аннан инде Рабигага эш белешермен. Бер дә борчылмагыз, мин сезне үзем белән алып китәм Казанга.

Хәлимә апайның күзләренә яшь тыгылды. Бердән, шулай бөтенләй чарасыз хәлдә кешегә мәшәкать тудыру өчен өзгәләнсә, икенчедән, Әхмәтсафаның миһербанлы, игелекле булып, алар өчен борчылуын күреп, күңеле йомшарып китте.

Казан дигән шәһәр хакында күпме ишетте ул, ә менә үзе дә шунда барып көн итәчәге төшенә дә кермәде. Казанга

китү дигәнне ишетсә, йөрәге әллә нишли, бик ымсындырса да, күңеле борчыла, һич кенә дә аягы тартмый иде шунда. Ерак, ят шәһәр, күз күргән җирләр түгел. Үзе гомер кичергән Атбасарын сагынып яши, хәтта холыксыз, дуамал ире Мөхәммәтҗанга да бер ачуы да юк сыман. Исенә төшсә, үзәкләре өзелә — үзсүзле картына Каргалыга килеп җиткәч тә хәбәр салганнар иде, җавап җибәргәне юк. Шулай аралары тәмам өзелер, килеп хәлләрен дә белмәс микәнни?.. Ни дип әйтәсең, яшь бичәсе белән чөкердәшеп тик ята торгандыр инде, Хәлимәдә, балаларда кайгысы юк. Казан дигәндә, шунысы бар бит әле, Хәлимәнең бабалары шушы яктан, Казан татарлары, күптән инде Атбасар якларына килеп чыгып, төпләнеп калганнар. Казанга бару түгел, Казанга кайту булыр иде, Әхмәтсафаның нияте барып чыкса...

* * *

Казанга сентябрь ахырларында килеп төште Әхмәтсафа. Казан Оренбур түгел, Хива-Бохараларны телгә дә аласы юк, Казан — Европа шәһәренә тартым.

Татар коммунистик университетында инде укулар башланган. Тиешле эшләрне үтәп, кәгазьләрне тәртипкә китереп, тулай торакка урнашканчы, октябрь ае да җитте.

Оренбурда озак тоткарлануының сәбәбе, әйтсәң-әйтмәсәң дә, Мусага — аның яшьлек дустына барып тоташа иде. Муса июль аенда ук Мәскәүгә китеп барган. Әхмәтсафа аның белән сирәк булса да хат алыша иде, соңгы хатында Муса: «Мин Оренбурда август ахырына кадәр булам, миңа кагылмыйча калма, Казанга бергә китәрбез»,— дип язган иде, Мәскәү университетына укырга керергә китеп барган булып чыкты. Әлеге хәбәрне ишеткәч, Әхмәтсафага кыен булып китте. Каргалыга кайтып кергәч тә, озаграк юанды, шундук Мусаны эзләп калага юл чыгасы калган да... Артык ышанды шул. Хәзер инде таныш булмаган шәһәргә ялгызы чыгып китәргә туры киләчәк. Хәер, артык катлаулы эш булмас анысы, егет илләр гизеп кайткан кеше бит. Муса булса, аны Оренбурда тоткарлап маташмаслар иде, шул гына.

Губкомда Әхмәтсафаны күктән иңгән бәхет дип кабул иттеләр. Комсомолның губком секретаре, Әхмәтсафаның Казанга укырга китәргә җыенып, документлар хәстәрләп йөрүен белгәч, сөмсере коелып кырт кисте:

— Бернинди Казан юк, иптәш Дәүләтъяров. Һәркайсыгыз җә Казан, җә Мәскәү дип хыяллана. Губернада кем эшләр? Мәнди анасымы? — Әхмәтсафаның аңа каршы төшәргә маташуын күргәч, бөтенләй кызып китте.— Юк булгач, юк! Рөхсәт итә алмыйм! Әнә Муса урыны буш, хәзер үк

вазифаңны кабул итеп ал да, эшкә тотын. Сине Казанда беркем дә көтеп тормый, беркемгә кирәгең дә юк. Барыгыз да интеллигент булмакчы. Беләсеңме, Совет иле сезнең ише интеллигентиклардан гарык инде, аларны корабларга төяп, чит мәмләкәтләргә юкка гына озатмыйбыз! Кирәге юк аларның. Безгә башы юк-бар акыл белән тулып, диңкеп, сөрсеп бетмәгән кыю эшче-крестьян яшьләре кирәк. Хезмәт урыннарында тормыш университетын үткән, коммунистик аңга ия булган бер кешене институт тәмамлап, диплом алган ун белгеч тә алыштыра алмый. Аңлашылдымы, иптәш Дәүләтъяров? Аңлашыла, әмма төшенеп җитмисең. Сиңа бер генә юл — губком үзенә эшкә чакырып торганда, сөенә-сөенә кил, сузып йөрсәң, мондый урыннан бөтенләй колак кагып куюың да мөмкин.— Губком секретаре, сүзен тәмамлап, мәсьәлә хәл ителгән чамасында егетне бүлмәсеннән чыгарып җибәрде. Ишекне япканда аның: «Кадрлар бүлеге уңнан өченче ишек, гариза яз да...» — дигән сүзләре генә ишетелеп калды.

Губком бинасыннан чыккач, Әхмәтсафа исәнгерәгән кыяфәттә шактый басып торды. Кесәсендә инде җәй башында ук килгән чакыру кәгазе. Ирексездән шул язуны капшап карады, фирка билеты белән ни эш кылырга? Исәпкә басмый ярамый. Фирка дисциплинасы катгый. Исәпкә бассаң да харап, кире исәптән төшеп йөргәнче ярты ел үтәчәк. Ярый, исәпкә басып тормадың ди... Анысын Казанда хәл итәр ул. Тагын бер кыенлык бар: аның эш кәгазьләренә «Әхмәтсафа Дәүләтъяров Оренбур губерна комитеты карамагына җибәрелә» дип язылган. Моны Рәҗәпов — Хорезмдагы түрә белеп эшләгәнме, әллә, чыннан да, тәртип буенча, кеше юллама белән кайдан килгән, шунда кайтарып җибәрелергә тиешме, егет уйлап-нитеп тормаган иде ул чакта. Шуның аркасында торткарлык та була язды менә. Кат-кат сызланды егет: их, Муса булса-а! Моның ише хәлләргә төшеп, айдан артык вакытын сарыф итмәс иде лә ул... Йөреп-йөреп тә, губкомнан кирәкле язу ала алмый юлга чыгып китте.

Казанга килгәч, бәласен аз татымады. «Оренбур губкомыннан рөхсәт язуың юк»,— дип, тулай торактан урын бирми азапладылар. Бәхеткә каршы, ТКУ директоры, үзе дә күптән түгел генә Мәскәүдән җибәрелгән илле яшьләр тирәсендәге хәрәкәтчән яһүд адәме — Алексей Абрамович Вольфович, егетнең каңгырып йөрүен күреп алып, тулай торакка урнаштырып ук куйды.

...Яшьләр булган һәр җирдәге кебек үк университет та гөрләп тора. Әхмәтсафа монда үзенең элекке сабакташы Фатыйх Сәгыйтовны очратты. Ул инде сүзгә, фаразларга, коткы салырга оста, Әхмәтсафаның ТКУга керүен белеп алгач, астыртын гына чеметеп тә өлгерде:

— Оренбур сәүдәгәрләре Казанга җыелып бетә болай булгач...

— Мин сәүдәгәр түгел,— диде Әхмәтсафа, каты итеп. Әлеге сүзнең үзенең башына бәла булып төшәчәген сизенгән сыман.— Үз тамагын үзе туйдырган крестьян баласы булам мин! Әйләндермә юкка кеше башын.

— Алайса, тыныч бул. Нигә соң бу тиклем өректең? — дип көлгән булды Фатыйх.— Мин бит болай гына, электән үк белгән кеше буларак кына...— Бөтенләй көтмәгәндә сорау бирде: — Үзең кайсы якта соң син? Кем тарафдары?

Әхмәтсафа сәерсенеп китте.

— Ничек кайсы якта? Белүемчә, без барыбыз да бер якта — совет ягында, совет тарафдарлары.

— Һә-һә...— Фатыйх мыскыл иткәндәй чыркылдап алды.— Ялгышасың, егет. Бу бит Казан! Казан ул бер генә минут та кайнамый тормый. Самовар сыман пар бөрки, әче төтен тузгыта-тузгыта кайный ул Казан. «Уң»нар да бар, «сул»лар да җитәрлек. Солтангалиевчеләр үз якларына тарталар, троцкийчылар үз якларына, инде Хатаевич, өлкә комитеты секретаре: «Туйдым бу татарларның бер-берсен чәйнәүләреннән, китәм, минем урынга башка кеше табыгыз!» — дип, Сталинның үзенә үк барып җиткән, ди.

— Син тамчы да үзгәрмәгәнсең, һаман элекке Фатыйх. Белмәгәнең юк.

— Дөнья өйрәтә ул,— диде Фатыйх, мактанган сыман. Ачылып китеп, акыл да сатып алды.— Белсәң-белмәсәң барысына кысылган бул, сүз әйтеп кал, бу кешенең үз фикере бар, дип уйласыннар. Шулай булмаса, ни пычагыма соң ул уку дигәннәре? Кесәдә кәгазь йөртү өченме? Хәзердән үк үзеңне күрсәтергә өйрән, күрсеннәр, исләрендә калдырсыннар. Укуны тәмамлагач, эшкә биш куллап кабул итәрләр. Минем караш шулай. Бәхәстә — хаклык!

— Белсәң-белмәсәң кычкырып, нинди хаклыкка ирешмәкче буласың?

— Ә син белеп кычкыр. Мин үземчә барам.

Әхмәтсафа, бәхәсне күпертеп җибәрмәскә тырышып, Фатыйхтан Оренбурда укыган танышлары хакында сораша башлады. Фатыйх, һәр сабакташын атаганда, ничектер борынын җыерып ала. Саный башлады:

— Муса инде зур кеше — шагыйрь. Фатыйх Исхаков та Мәскәүдә. Нургали ага Надиев — гыйльми үзәктә. Миңа салкын карый ул кеше, мин аңа нәрсә эшләгән? Зиннәт, Саттарларны үзең беләсең, Казан шулпасын чөмерәләр, һәркайсы белем алабыз дип тилмереп йөри. Иң кызыгы — Кәрим, шул Каргалы борчасы да, Казанга килеп, каядыр укырга кергән дип ишеттем.

Кәрим исемен ишеткәч, Әхмәтсафаның кәефе төште. Вәлкәй хаҗиның сүзләрен әле ул Гомәрханга да әйтми торган иде. Тел сөяксез, ни сөйләмәс, үзем ныклап эзенә төшәрмен дип уйлап та йөргән иде. Каргалыда шуны белде, Абдулла гаиләсен алып авылдан китеп тә барган икән. Җаек шәһәре тирәсенә дигән сүзләр генә ишетә алды. Кәримне күреп белешсәң, начар булмас иде...

Инде китәм дигәндә, Фатыйх янә Әхмәтсафаның касыгына төртеп алды.

— Карале, беркөнне Заһидәне күрдем. Хәтерлисеңме, ТИНОда... артыннан чабып маташкан идең. Ул сине Бохарада очратканын сөйләп бирде. Шәп кыз, башкалар кебек борынын өскә чөйми. Теге вакыттагы саташулары беткән, җитди кызга әйләнгән. Хәзер медицина институтында укый икән. «Такташ белән хыялланасыңмы?» дигән идем, көлә, «Җүләр чаклар үтте инде» ди. Шәп кыз, күзең төшеп йөри идең, боткагыз пешмәде, ахрысы. Хәзер ничек соң, яңабаштан гыйшык-мыйшык уенына керешмисеңме?

— Минем ярәшкән кызым бар.— Йөрәге кысылып куюын сиздермәскә тырышкандай, йөзен читкә борды. Заһидә исемен ишетү түгел, искә генә килеп китсә дә, битараф кала алмый ул. Күз алдына килә дә баса. Югыйсә инде күңеленнән сызып атканга бишбылтыр кебек, искә төшсә, үзәге өзелеп куя, каһәр. Кызның Казанда икәнлеген белә Әхмәтсафа. Очрамаса гына ярар иде... Рабигасы бар аның. Кинәт ике ут арасында калгандай хис итте үзен.

Фатыйхның йөзендә көнләшү галәмәте чагылды.

— Ну, парин, кая ашыгасың син? Бөтен көймәнең койрыгын берьюлы тотмакчы буласың. Ярәшеп, вәгъдә бирешеп йөрмәсәң, кызлар беткәнме Казанда?

...Укулар башлангач, Әхмәтсафа башы-аягы белән дәреслекләргә чумды. Аның тырыш, укуга сәләтле икәнен Александр Айхенвальд — политэкономия укытучысы күреп алды һәм егетне студентлар түгәрәгенә тартты. Ул үзе Мәскәүдә Кызыл профессорлар институтын тәмамлаган, Бухаринны якыннан күреп белгән, аның идеяләре белән янып, илһамланып яшәүче галим иде.

Фирка җитәкчеләре арасында фикер аерымлыклары барлыгын Әхмәтсафа аңлый, Айхенвальд түгәрәгендә бу хакта еш кына бәхәсләр дә килеп чыга, остазы кебек үк бәхәстә табылган хакыйкатьне генә хакыйкатькә саный, тыныч тормыш төзүгә йөз тоткан илдә бәхәс, тартыш-даулардан битәр, ил үсешен тизләтүче мөһим бер чара, имеш. Бәхәстә иң кирәклесе — башкаларны да тыңлый белү. Менә монысы җитми тек җитми инде студентларга. Яшь әтәчләрдән ким кы-

ланмыйлар. Айхенвальдка, аларны тынычландыру өчен, шактый тир түгәргә туры килә. Әхмәтсафа Татпрофсовет каршында пролетстуд, ягъни эшче-студентлар бюросында эшләгәнлектән, Мәскәүдәге фирка җитәкчелегенең фикер көрәшен игътибар белән күзәтеп бара иде. «Уң»нар юлбашчысы Бухарин яклы профсоюз башлыгы Томский карашлары да аңа якын иде. Күреп тора, «сул» Троцкий белән Бухарин яклыларның бәхәсе, тора-бара чикләрне үтеп, ярсулы тартышуга әйләнеп бара, бусын егет өнәп бетерми, гел үзеңнекен генә хак дип раслау, башкаларның фикеренә колак салмау куркыныч юлга да алып кереп китәргә мөмкин бит. Сталин исә бәхәсләргә бик катышмый, ара-тирә кызган табага май салган кебек, каршы якның әле берсен куәтләп, әле икенчесен үсендереп, тартышны тагын да кискенләштереп кенә җибәргән кебек. ТКУның үзендә дә тыныч түгел. Вольфович белән Айхенвальд арасында ачыктан-ачык бәхәс купты. Акылы, йөрәге белән Айхенвальд яклы иде егет. Вольфович — тарихчы, Татарстанда гражданнар сугышы тарихын өйрәнә. Күрәсең, Татарстанда яшәгән кыска гына арада шактый мәгълүмат туплап өлгергән, кызыклы, мавыктыргыч итеп сөйли. Татарстан Республикасы төзелү чорында «уң»нар Мохтаров, Шамил Усманов кебекләрнең Казанга Солтангалиевне кайтарырга омтылышын кискен гаепләп чыга. «Сул»ларның Сәхипгәрәй Сәетгалиевне яклап тартышуларын, ахыр чиктә, Сталин фикеренә таянып, Үзәкнең «сул»ларны алга чыгаруын, Татреспублика башына Сәетгалиев куелуын дөрес гамәлгә санап, бу хәлне хакыйкатьнең җиңүе итеп, мисал рәвешендә китерә иде. Әйе, кызык дәверләр булган. Әхмәтсафа бераз гына соңрак туган шул, әлеге дауда катнаша алмавына уфтанып та куя. Вольфович егетне хыялланып утыруыннан җиргә төшерә, ул инде Грасис, Шәмгунов кебек коммунистларның тетмәсен тетүгә керешкән. Болар, гомумән, милли республикалар төзүгә каршы төшкән ахмаклар, милли сәясәттә чеп-чи наданнар... Вольфович белән килешми булмый, дөрес әйтә, милли мәсьәләдә сай йөзгән бәндәнең сәясәттә эзе булмаска тиеш!

Телгә еш алынган кешеләр арасында Әхмәтсафага азмыкүпме таныш ике адәм бар. Беренчесе — комиссар Шамил Усманов булса, икенчесе — Оренбур большевигы Гали Шәмгунов иде.

Шамил Усмановны солтангалиевче буларак 1920 елда ук Казаннан җибәргәннәр икән. Ул Урта Азиядә Көнчыгыш фронт карамагында көн күрә, аннан янә Мәскәүгә килеп төпләнмәкче була. Тынгысыз татар комиссарының мәркәздә яшәвен өнәмәгән фирка җитәкчеләре Усмановны тагын Казанга озату чарасына керешкәннәр дигән хәбәрләр йөри.

Студентлар арасында легендар комиссарның абруе зур, күпләрнең, шул исәптән Әхмәтсафаның да, комиссар белән күрешәсе, сөйләшәсе килә.

Гали Шәмгуновның исеме Оренбурда инкыйлабның җиңеп чыгуы белән аерылгысыз. 1918 елдагы хәлләр дә тарихка кереп калган. Февраль аеннан апрель башларына кадәр Оренбур төрмәсендә яткан Зәки Вәлидине «ликвидировать» итәргә рөхсәт сорап, Үзәккә мөрәҗәгать иткән үҗәт бер коммунист ул Шәмгунов, килешмәүчән большевик. Сталин, бу мәсьәләгә сак карап, Шәмгуновка ашыкмаска киңәш бирә, чаманы онытып җибәргән коммунистны шелтәләп, арт белән киртә җимерүен хупламавын белдерә. Зәки Вәлидидә үҗәтлек җитәрлек. Ул «өченче юл» тарафдары. Шигаре — «Без большевиклар да түгел, меньшевиклар да түгел, без — башкортлар!» Андагы көч, дәрткә сокланып карый иде Әхмәтсафа. Тәки барлык каршылыкларны үтеп, Рәсәйдә беренче милли республика — Башкортстан төзүгә ирешә, аның беренче илбашы була. Шәмгунов тырнагыннан исән калдырганы өченме, Зәки Вәлиди Сталинны милли проблемаларны иң яхшы белүче дип саный, аңа ышанып, кызыллар ягына чыга. Әмма соңыннан бу гамәленә үкенә дә. Кызыллар ягына күчкән чакта коралсыз башкортларга күрсәткән җәбер-золымны мәңге онытырлык түгел шул. Сталинның икейөзле җан булуына тәмам инанып, бу кешедән өмете киселеп, ел ярымнан соң, 1920 елның июнендә Бакуга, аннан Урта Азиягә китә Зәки. Әхмәтсафа Хивада эшләгәндә әле үзбәкләр арасында Вәлидигә хөрмәт зур иде. Вәлиди хакында андагы укымышлы кешеләр авызыннан күп тапкырлар ишеткәне булды. Аның Ленинга атап язган хатындагы «Сак булыгыз! Милли сәясәтнең барлык ялгышлары башында Сез үзегез торасыз булса кирәк» дигән сүзләрен хәтеренә салып куйган иде. Вәлидиләр буыны нык холыклы, иманлы буын булган шул, дип сокланып куя кайчак Әхмәтсафа. Хәзер аумакайлык, ярарга тырышу тамырланып килә яшьләр арасында. Вәлиди әнә үзен Сталинның кат-кат Мәскәүгә чакыруын да санламый. 1923 елда ук Советлар иленнән киткән кеше буларак, аны ил, милли сәясәткә хыянәт иткән кеше дип телгә алалар. Әхмәтсафа да акламый аның кыланышларын, әмма хөрмәткә лаек бу шәхес, монысы бәхәссез иде.

Боларны искә алу да шуның өчен: әгәр Татарстан Республикасы төзелгәндә Шамил Усманов кебек якташлары җан атып, тартышып йөргән икән, аңа да Казан бөтенләй үк читят түгел, димәк. Казан — бөтен татарның мәркәзе, бөтен татарны җыеп торучы шәһәр. Шушы уй аның күңелен җылытып җибәрә, укуга дәртен тагын да арттыра иде.

...Утсыз төтен чыкмый, диләр. Каршы килер сүзләр тү-

гел икән. Озак та үтмәде, Казанга күченеп кайткан Шамил Усманов үзе ТКУга килеп керде, студентлар алдында чыгыш ясап китте. Студентлар клубында булды әлеге очрашу. Берничә укытучы озатуында (алар арасыннан Гомәр Шаһиәхмәтовны, ягъни Толымбай тәхәллүсле мөгаллим-язучыны гына беләә Әхмәтсафа) җил-җил атлап килүче нык, ыспай гәүдәле, коңгырт чәчле яшь кешене тамашачылар кул чабып каршы алдылар. Комиссар Усмановның яшьләр арасында абруе зур иде һәм моңа сәбәпләр дә бар. Ул — гражданнар сугышын башыннан ахырына кадәр кичеп чыккан гаярь комиссар. Казанда әле 1922 елларда ук радио мәсьәләсе буенча чыгышлар ясап йөргән кеше, 1924 елда бөтен шәһәр халкы катнашында диярлек, исәпсез-сансыз гаскәрләр белән гаҗәеп тамашалар үткәреп, Казанның дүрт көнгә йокысын алган шәхес. Китаплары чыга, сәхнәдә аның спектакльләре уйнала. Инде менә тамаша предприятиеләре идарәсе һәм ерак дулкында тапшырулар алып баручы радиостанция төзелеше җитәкчесе итеп билгеләнгән. Бөтен Казанны дер селкеткән могҗиза — җиденче ноябрь көнне беренче мәртәбә Татарстан башкаласында радиотапшырулар да оештырып җибәргән кеше ул. Күп кенә студентлар аның аэродинамика клубын оештыру өчен җилкенеп йөрүләрен дә онытмаганнар икән. Кыскасы, Шамил Усманов барысына да якын, һәркемгә таныш, билгеле шәхес, шуңа студентлар аны котырып кул чабып каршы алдылар да инде.

Усмановны күреп алган уңайга, Әхмәтсафаның йөрәге кысылып куйды. Бер карасаң, һич тә үзгәрмәгән сыман комиссар, икенче карасаң, тагын да җитдиләнгән, олпатланган.

Очрашуны Гомәр Толымбай ачты. Усманов, үзенә сүз бирелүгә, җәһәт кенә трибуна артына килеп басты һәм, өстенә кигән өр-яңа костюмына җай гына ишарә ясап, көлемсерәп, сүз башлады:

— Ун елдан артык хәрби киемнән йөрергә туры килде. Гади кәчтүмгә һич иялэшеп булмый. Сүз сөйләргә чыксаң, нәрсәдер җитми, тотып торыр көч юк шикелле.

Зал күңелле генә гөжләп алды.

Усманов, моңа артык игътибар итмәгәндәй кыланып, күзен бермәл түшәмгә төбәп торды, ул морадына ирешкән иде инде — тамашачылар белән үзе арасында элемтә урнашуын тоеп, төп сүзгә күчте.

— Соңгы айларда булып үткән вакыйгалардан тетрәнгән күңелем һаман үз урынына утыра алмый әле,— диде ул, дәһшәтле хисләр кичергән тавыш белән. Аның чыгышын Әхмәтсафа Каргалыда ук ишеткәне бар. Аерма бар иде бу ике чыгыш арасында. Ул чакта артык көчле булмаган тавышы ныгыган хәзер, һәр сүзе күңел түренә үтеп керә. Анда каба-

лану юк, хәтта тыңлаучыларны шул беренче җөмләдән үк авызына карата алуына ниндидер канәгатьлек хисләре дә кичерә сыман.— Август ахырларында Нью-Йоркта Сакко белән Ванцеттиның үтерелүе турында хәбәр килеп ирешә. Җаным елады ул көннәрне. Радио. Траур маршы. Күз алдыма үзем кичкән гражданнар сугышы еллары килде. Утлы, давыллы еллар. Революция өчен һәлак булган көрәштәшләр. Ком бураны, күз карашын, сулышны буа торган ком бураны... Өермә. Пәри туе. Яктылыкны капларга тырыша, күзне томаларга азаплана бу өермә. Аннан ком бураны тына, көн яктыра, тирә-юньдә тынлык, өермә-мәхшәр булмаган да кебек. Барысын да онытасы килә шушы минутларда. Юк, онытырга ярамый. Нью-Йоркта булган хәлләр якын киләчәктә капитал белән бәрелешнең неизбежностьлыгын күрсәтә. Сез, татар студентлары, сәясәт мәйданы сулышын, җилнең кайсы тарафка исүен, кайсы агачның кайсы яфрагы нәрсә дип кыштырдавын ачык белергә, аңлап торырга тиешсез. Әле партиядә дискуссия бетте дип тынычланырга иртә. Тормышның һәр почмагында восстановительный процесс — төзү пульсының көчле тибүе сизелә. Татарстанда группалар тынмыйлар, кайчандыр мин араларында йөргән «уң»нар хәзер көннән-көн физиономия-чырайларын ача барып, татар буржуазиясенең төп яклаучысына әйләнгәнлеген күрсәтәләр. Сезнең кебек үк миңа да политэкономия, сыйныфлар көрәше тарихы фәннәрен тирәнтен өйрәнергә туры килә. Алар миңа күп нәрсәне танырга ярдәм итте, күземне ачты.

Зал тын да алмый Усмановны тыңлый, Гомәр Толымбай, янәшәсендә утырган икенче бер кунакның колагына нидер пышылдап, тыенкы гына көлеп куйды. Тегесе, ризасызлык белдереп, җилкәсен сикертеп алды. Моны Усманов сизеп алды һәм, аптыраулы күзләрен тутырып, Толымбайга караш ташлады. Гомәр Толымбай үзе дә сизмәстән урындыкка сеңә төште. Уңайсызланып, башын түбән иде. Усмановның әлеге хәлдән кәефе килепме, күтәренке тавыш белән сүзен дәвам итте:

— Әйе, революция вакыйгалары искә төшә дә ирексездән хатирәләр өермәсе чолганышында каласың. Хатирәләр белән генә юанып яшәргә иртәрәк әле безгә. Көрәш туктап тормый, иптәшләр. Хәзер төп көрәш латинга күчү мәсьәләсе тирәсендә бара. Череп беткән искелек тарафдары Гыймад Нугайбәк, аның иярченнәре, тарих тегермәненә таяк тыгып, вакыт агышын акрынайтмакчы булалар. Иске язуны сипләштереп кенә татарны яңа тормышка үстерәп алып кереп булмый ул! Барып чыкмас! Гыйльми үзәктә Галимҗан Ибраһимов яңалифкә күчүне ашыктырмый. Аның тарафдарлары — Җамал Вәлиди, Галимҗан Шәрәф кебек шәкерт-

агайлар, гарәп хәрефе койрыгына ябышып, социализмга килеп чыкмакчы булалар...

Шул чагында залда Фатыйх Сәгыйтов, ут капкан кебек, урыныннан сикереп торды һәм ярсулы тавыш белән:

— Куарга аларны Казаннан! — дип кычкырды.— Эзләре булмасын! Газетага мөрәҗәгать белән чыгыйк. Җитте татарның башын бутарга! — диде дә ничек чәчрәп торса, шулай ук шып туктап, урынына чүкте.

Усмановның битенә кызыллык йөгерде. Ул, сүз җебен чуалткандай, бераз тын торды да сүзен әкрен генә дәвам итте:

— Куып кына мәсьәлә хәл ителми, иптәшләр. Без һәр кешене, фикер аерымлыгына карап, илдән куа башласак... Андыйларга иң көчле удар — массаларның җавабы. Әгәр масса, ягъни татар халкы, тулаем яңалифне яклый икән, моңарчы су болгатып яткан күгәргән мәдрәсә хәлфәләренә ни кала? Әйе, тончыгачаклар алар үз күлләрендә. Безгә менә шушы юлдан бару кирәк. Иң мөһиме: безне яшьләр якласын. Газеталарда минем чыгышларны укый торгансыздыр, Шәрәф Борһан, Сәләх Атнагулов иптәшләр тырышлыгын да искә алырга кирәк — барысы да яңалифне яклыйлар. Тагын шунысы да бар — латинчага күчү мәсьәләсенә урыслар да битараф түгел. Кириллица, әйтүләре буенча, аларны да канәгатьләндерми икән. Луначарский, Яковлев кебек галимнәрнең фикерен ишеткән, укыганыгыз бардыр инде. Урыслар безгә караганда да өлгеррәк булып чыктылар, аларның ныклап хәзерләнгән өч проекты бар латинчага күчү буенча. Шулай итеп, киләчәк латин файдасына хәл ителәсе көн кебек ачык.

Әхмәтсафа өчен бусы яңалык иде. Димәк, латин мәсьәләсе уйлаганга караганда да тамырлырак булып чыга болай булгач.

Усманов кызып сүзен дәвам итте:

— Яңалиф — көн таләбе. Гарәпчә язу дигән булып, балаларның телен бозудан туктарга вакыт. Мин, гарәпчәләп язуның хилаф яклары хакында йөзләгән мисаллар китереп, чыгышлар ясадым. Кабатлап тормыйм. Шунсы кызганыч, әлегәчә өлкә комитеты шул хәлфәләрне яклап маташа...— Усманов бераз гына дәшми торды.

Димәк, әлифба мәсьәләсе иң беренче чиратта дингә каршы юнәлдерелгән чара булып чыга түгелме соң? Халыкның нинди хәреф белән язуы сәяси гамәлгә әйләнә икән бит. Язу — аерым бер сәяси вазгыятьтә халыкның аңын, фикер юнәлешен билгели булып чыга. Мондый эштә уйламый адым ясау төзәлмәс хаталарга китермәсме? Күрәсең, Галимҗан Ибраһимов моны аңлап эш йөртә. «Хата ясап аны төзәтүгә караганда, аны алдан күрү хәерле»,— ди иде Оренбурда

Гомәр агасы. Гел сакланып, ул-бу булмасын дип, алны-артны карап кына яшәп тә булмый ич! Иске белән көрәшми, аны тәмам тар-мар итми торып, яңага ирешеп булмаячак икәнен дә яхшы аңлый. Усмановка ышана ул, яңалифкә каршы килүне урынсыз дип саный. Әхмәтсафаның яшьлеге инкыйлабка туры килде, аның хәзер өлгереп килгән чагы, аң-зиһене, дөньяга карашы революция җилләре алып килгән өермәле яңгыр астында бөреләнде, чәчәк атты, инде менә җимеш бирер вакытлар җитеп килә. Һәрнәрсәгә аның үз карашы булырга тиешле чор бу, үзе дөрес дип тапкан фикер-мәсләккә икеләнмичә кушылырга тиеш дип саный, шул мәсләк өчен көрәшергә дә туры килүе мөмкин. Бу яктан Усмановка сокланып карый ул, менә кеше ичмаса, һәр нәрсәдә эше бар аның, һәр нәрсәгә үз фикере өлгереп җиткән, үз юлының дөреслеген раслап, ал-ялны белми көрәшкә дә ташланган әнә... Менә шундый көрәшчеләрдән үрнәк алып яшәргә кирәк тормышта. Әхмәтсафа, уйларыннан айнып, чыгыш ясаучыга текәлде.

Усманов исә күкнең җиденче катында талпына. Яңалифкә күчүне дөнья пролетариаты башлап җибәргән революцион көрәштә тәүге адымнарның берсенә санап, шушы күчеш белән генә тукталып калмыйча, һаман алга табан баруның зарурлыгын исбатларга кереште. Киләчәктә тагын бер кирәкле адым ясау мөһим булачак — ул да булса эсперантога күчү. Бөтендөнья күләмендә. Усманов, ялкынланып, эсперанто турында нотык тота башлады. Көтмәгәндә, тамашачыларга карап:

— Чу ви пороляс эсперантэ? — диде. Аның күзеннән шаян чаткылар чәчелде.

Әхмәтсафа моны аңламаса да, эсперантода ниндидер сорау бирелгәнен аңлый иде, янәшәдә утырган кемдер:

— Нэ, ми нэ пароляс эспирантэ,— дип җавап та кайтарырга өлгерде.

Усманов чын күңелдән көлеп җибәрде.

— Аңлагансыз бит. Мин: «Сез эсперантода сөйләшә беләсезме?» — дип сорадым. «Юк, без эсперантода сөйләшә белмибез»,— дигән җавап ишеттем.— Аннан ул янә җитдиләнде.— Белергә кирәк. Үзлегемнән немецча өйрәндем, эсперанто буенча дәреслек язып бастырдым. Тора-бара Җир шарындагы барлык халыклар эсперантода сөйләшә башлаячаклар. Шунсыз бөтендөнья халкы арасында нинди туганлык, үзара аңлашып яшәү булсын ди. Бөтендөнья пролетариаты — эсперантога!

Студентлар гөрләшеп кул чаптылар.

Усманов, кулын күтәрә төшеп, гөжли башлаган залны тынычланырга чакырды:

— Минем килү яңалифне мактау өчен генә түгел иде. Бу инде хәл ителгән мәсьәлә дип аңларга кирәк. Вакытны сузуга эч пошып кына сөйлим. Күңелне тырнап торган бер нәрсә бар — гарәпчелекне яклаучылар, берләшеп, Үзәк Комитетка, иптәш Сталинга хат язганнар. Төркем актив эшли, хәзер галимнәр, язучылар, студентлардан имза җыю бара. Аң булыгыз, әгәр шундый кешеләргә тап булсагыз, провокацияләргә бирелмәгез, имза куймаска чакырам.

— Б...лы пумала белән куып чыгарабыз,— дип әтәчләнде Фатыйх Сәгыйтов.

Ул арада студентлар Усмановка сораулар яудырырга тотындылар. Сүз нигәдер, яңалифне урап үтеп, әдәбият тирәсендә куерды.

— Соңгы вакытта нинди әсәрләр яздыгыз? — дип сорады бер кыз.

— «Памирдан радио»...— диде мәгънәле итеп кенә Усманов.

Әлеге әсәрне студентлар да яхшы белә иделәр бугай, кул чаптылар.

— Әкият бит ул...— дип мыгырданганы ишетелде Фатыйх Сәгыйтовның.— Әкиятнең чын әдәбиятка ни катнашы бар?

Әле генә үзен яклап, күтәрелеп бәрелгән егетнең кинәт үзенә үк каршы төшүенә аптырап, Фатыйхка сынаулы карашт төшереп алганнан соң, Усманов әдәбият хакында уйлары белән уртаклаша башлады.

— Әдәбият мәйданы — көрәш ул. Тиңсез көрәш. Мине татар әдәбиятында бердәнбер пролетариат язучысы дип әйтергә дә ярый торгандыр. Моңа Гомәр иптәш Толымбай да каршы килмәс дип уйлыйм.— Ул нигәдер муенын боргалап алган Толымбайга дустанә карап алды.— Ләкин мондый «беренчелек» мине шатландырмый. Артка борылып карыйм да кашларымны җыерам. Юк, арттан ияреп килүче яшь көчләр күренми. Алмаш күрмим. Шул борчый мине. Син, яшь иптәш, әкият, дисең... Бәлки, сәламәтлегем түзеп, мин алдагы көрәшләргә җитәрмен, тагын да гамьле, тагын да җанлы вакыйгалар кичерермен. Бәлки, күз алдымда җиңгән пролетариат Европасын күреп, коммунизм төзүдә катнашырмын... Ни булса булыр, әмма ул еллар, бүгенге көрәш сафлары, беренче ашкынулар тәкрарланмаслар. Аларны күздән югалтмас өчен, эшкә тотындым, язам да язам. Каләм җиткән кадәр ул минутлардан күзгә чагылган, күңелдә калганнарын суырып алып, яшь буынга укытыр өчен мәйданга чыгарам. Киләчәк буын унҗиденче ел коммунистларының тормышын белсен, дим...

Бу сүзләрдән соң нигәдер моңсу булып китте. Әхмәтсафа, үзе дә сизмәстән, урыныннан сикереп торды.

— Шамил абый!.. — Олы язучыга, сугыш батырына шулай үз итеп эндәшүеннән кыенсынып, төртелеп калды. Үзен кулга алып: — Иптәш Усманов, — дип, рәсмирәк тонга күчте. — Сез мине оныткансыздыр инде. Унтугызынчы елда Хәйбри дигән командир Каргалы авылында дуамал кылана башлагач, мин Оренбурга, сезнең штабка килеп хәбәр иткән идем...

Усманов, гаҗәпләнә төшеп, алдагы рәттә басып торган Әхмәтсафага бераз карап торды да, елмаеп, аңа каршы килде, нык кына итеп кулын кысып, җилкәсеннән кочаклаган хәлдә, йөзе белән тамашачыларга борылды:

— Исемә төште. Бу егет элемтәче булды ул көнне, — диде. — Әгәр вакытында килеп җитә алмаса, Каргалыда хәлләр була иде... Хәйбри дуамал иде шул. Шул дуамаллыгы аркасында Тозтүбә тирәсендәге сугышларда башын салды да. Сагынам мин аны... Ул елларны сагынам... Рәхмәт, егет, искә төшерүең өчен рәхмәт. Әйе, ул еллар онытылмый, истән чыкмый. Йөрәккә уелган хәлләр бар...

— Безне сөендереп, күңелләргә үтеп керерлек итеп, яңа әсәрләр язгыз, — диде Әхмәтсафа, халык алдында басып торуын яңа гына абайлап алгандай. — Соңгы елларда Урта Азиядә булып, әдәбият яңалыкларыннан артта калдым. Куып җитәрмен дип ышандырам...

— Әйе... — диде Усманов, трибуна артына кире барып баскан иде инде һәм сүзен дәвам итте. — Язарга кирәк, язучы бит ул кулы кычытканга язмый, кирәк булганга, тиеш булганга яза. Мин әдәбиятны матурлык сөйгәнлектән сөймим, әгәр дә әдәбият революциягә корал була алмаслык булса, мин аңарга тотынмаган булыр идем кебек... Мин художникмы, әллә мастермы? Художникның элекке мәгънәсе белән алганда, матурлык өчен рухланып язучыга санаганда, мин ул түгел. Мин, аерым тойгылар, мәхәббәт, башка сыйфатлар белән генә хисаплашып, аларны тикшерергә уйлыйм. Миңа инсаният, коллектив дигәннең тәкъдире кирәк. Аның кайгысы, шатлыгы, тойгылары миңа азык. Шуларны язарга уйлыйм...

Очрашу бетеп, кул чабулар тынып бетмәс борын, Усманов янә Әхмәтсафа янына килеп басты.

— Исемеңне онытканмын, энекәш... — диде ул, гаепле хис иткәндәй. — Һич хәтергә төшми.

— Әхмәтсафа мин, Дәүләтъяров булам.

— Таныш фамилия. Дәүләтъяровларны Оренбурда укымышлы кешеләр дип беләм. Шулар нәселеннәндер бит.

— Гомәр агай безгә туган тиешле.

— Шулайдыр, шулайдыр. Менә бит, тау белән тау гына очрашмый. Кайларда йөреп, җирләр-илләр кичеп, Казанга килеп чыккансың, бу очрашуга чынлап сөенәм мин.

Усмановны башка студентлар да урап алган иде, ул, ашыга төшеп, Әхмәтсафага кулын сузды.

— Югалма күздән. Концертларга йөрисеңме? Асия Измайлова концертларын калдырма. Искиткеч җырчы! — дип, чыгу ягына кузгалды. Ишек төбенә кадәр студентлар камалышында барды ул.

— Ну, егет, моменттан файдалана беләсең! — Фатыйх Сәгыйтовның күтәрек тавышы Әхмәтсафаны сискәндереп җибәрде. Фатыйхның төртмәле сүзләренә җавап кайтарып тормастан, сыйныфташ егетләре янына атлады. Сүз дә юк, аның абруе бу минутларда иптәшләре каршында, чыннан да, кисәк үсеп киткән иде.

* * *

— Кеше яхшысын да, яманын да тиз онытучан. Хәтер дигән нәрсә хикмәтле нәстәкәй инде ул. Хәтерсезлектән мескенлеккә бер адым. Оныту — баш миенең иң әһәмиятле һәм мөһим үзенчәлеге. Әгәр күргән-белгәннәребез хәтергә теркәлеп бармаса, һәм кайсыдыр вазгыять кысасында кирәкле хәбәр хәтердә терелеп, кабат искә килеп төшми икән, кеше өчен фаҗигагә тиң тормыш башлана. Тиз онытабыз, хәтерне эшкә җигәргә яратмыйбыз. Шулай әйбәт була дип уйлыйбыз, искегә тисәң, исең китәр дип, кайбер вакыйгаларга кагылмыйча, булганны юк дип яшибез. Чын тарихчы болай эшләргә тиеш түгел.— Айхенвальд политэкономия буенча гыйльми түгәрәккә килүчеләргә каш астыннан сөзеп карап алды. Карашы Әхмәтсафага төртелде. — Беренче итеп, үземне борчыган нәрсәләр хакында сөйләшеп аласы килә... Әйтегез әле, һич аңлый алмыйм, әгәр политэкономия дигән фән бар икән, социализмда аның асылын тәшкил иткән акча — товар — акча дигән нәрсә барлыгын кире какмыйбыз икән, без төзи торган җәмгыять нинди юл белән үсәргә тиеш соң? Дәүләтъяров, сез инде дөнья күргән кеше, бу хакта ни уйлыйсыз?

Дәүләтъяров урыныннан күтәрелә башлаган иде, Айхенвальд, үзе дә әле чагыштырмача яшь кеше, аны кире утырырга мәҗбүр итте.

— Утырган килеш кенә җавап бирегез. Аягөсте хаклыкны яклап булмый, диләр бит...

Кемдер тел шомартып алды:

— Утырырга өлгерербез әле, иптәш Айхенвальд. Утырган хәлдә якларга туры килмәсен хаклыкны.

Айхенвальд, шаяртуны аңламаганга сабышып, җилкәсен җыерып куйды.

— Ну-у, сөйләшүне андый яссылыкка күчермик инде. Дәүләтъяровны тыңлыйбыз.

— Хуҗалык эшчәнлеге белән ныклап шөгыльләнгәнем юк, — диде Әхмәтсафа, башында бөтерелгән фикерләрне тәртипкә китерергә тырышып. — Урта Азиядә чагында шуңа игътибар иттем, әгәр икътисад өлкәсендәге сәясәт халыкка аңлаешлы икән, аңа диһкан каршы килми. Җитештергән продукциясен тиешле күләмдә дәүләткә тапшыра, салымнарны түләп бетергәч, продукциянең арткан өлешен хуҗалыгына файда китерерлек итеп сатып җибәрә. Сәүдә итә алса, аның хуҗалыгы бара, әгәр үстергән мамыгын мәҗбүр итеп дәүләткә тапшырталар икән, җитмәсә, аның өчен бернинди түләү дә булмаса, диһканга афәт килә, ачлык-ялангачлыктан иза чигә башлый, хуҗалык таркала. Хәерчелек янында, белгәнегезчә, үлем йөри. Андый хәлләр булды Хивада. Фәкать яңа икътисадый сәясәт нәтиҗәсендә генә диһканнар бераз хуҗалыкларын ныгыта алдылар. Югыйсә эшләр мөшкел иде. Ә болай дөрес кебек, товар — акча — товар формуласы яңа җәмгыятькә батмый. Өстәмә табышка юл ачылмый икән, җәмгыять икътисадый үсә алмый.

— Димәк, сезнеңчә, хакимият икътисадый сәясәтне ордым-бәрдем түгел, ә крестьян хуҗалыгының мөмкинлекләрен исәпкә алып үткәрергә тиеш. Дөрес аңладыммы?

— Шулай, җитештергән продукция хуҗалыкны ныгыту өчен эшләми икән, алдагы елларда, хәтта крестьян үзе теләсә дә, ул инде хуҗалыгын тарта алмаячак. Салым сәясәте хезмәт кешесен бөлдерүгә юнәлергә тиеш түгел дип саныйм. Товар җитештергән хуҗалык — илнең тоткасы ул. Без социализмны эшче-крестьян кулы белән төзибез, революция идеясен алар тормышка ашыра. Маркс сүзләрен хәтердән чыгармаска иде: идеяне тормышка ашыручы мәнфәгатьләрне санга сукмыйбыз икән, ул идея беркайчан да чынга ашмас.

Айхенвальд, җаваптан канәгать калып, аудитория алдында ике кулын артка кушырып, әрле-бирле йөри башлады.

— Болар бит шундый гади нәрсәләр. Моның өчен югары уку йортларын да тәмамлау кирәк түгелдер. Хәер, без хәзер массаларны укытуга нык әһәмият бирәбез. Укыйбыз, ачышлар ясыйбыз, ә хуҗалыкны һич кенә дә кирәгенчә алып бара алмыйбыз. Уйлап куям, барыбызда да югары белем бар, ә башлангыч белем юк. Башлангыч белем — нигез. Менә нәрсә җитми. Крестьян-эшчедә булган гади тормыш зирәклеге юк бездә. Аларда бар ул башлангыч белем дигәнең... Әле генә Вольфович белән бәхәскә кереп алдым. Бер төркем галим, җиң сызганып, Татарстанда революция, гражданнар сугышы тарихын язалар. Хәзерге пролетариат диктатурасы чорындаТатарстандагы хәлләрне ал да гөл итеп тасвирлаганнар. Әйтерсең һәм икътисадта, һәм сәясәттә ялгышлардан хали без һәм аларны төзәтергә дә кирәкми. Куркыныч юл.

Ялгышларны исәпкә алмасаң, бик тә гыйбрәтле үзенчәлек бар — алар кабатлана. Без әлегә беркатлы сәясәт алып барабыз, массаларның аңында борылыш ясарга кирәк дип лаф орабыз, үзебез исә хуҗалык итүдә бертуктаусыз ялгышлар җибәрәбез. Иң үкенечлесе — алар кабатлана тора. Шулай булгач, масса аңында үзгәреш буламы? Юк, булмый. Адәм баласы ялгышлардан сабак алырга тиеш. Борынгы Кытай фәлсәфәчесе акыллы кеше башкаларның ялгышыннан гыйбрәт ала, ахмаклар үз ялгышларыннан сабак ала, дип язып калдырган. Ә без ни башкаларның хаталарын өйрәнмибез, ни үзебез ясап ташлаган хаталардан сабак алмыйбыз. Аптыраш, нинди җәмгыять төзибез, кая бармакчы булабыз?..

Аудиториядә авыр тынлык урнашты. Айхенвальд, йөрүеннән туктап, уйлана төшеп, сөйләнүен дәвам итте:

— Әле яңа дәрескә материаллар эзләп утырганда, үзем өчен коточкыч яңалык ачтым. Бу хакта уйлана идем, сәбәпләре дә билгеле иде кебек, әмма кулда конкрет дәлилләр юк иде.— Айхенвальд өстәл өстендә чәчелеп яткан кәгазьләр арасыннан тиз-тиз үзенә кирәклесен эзләп тапты. Маңгаена күзлек менеп кунаклады, әрнүле тавыш белән тезеп китте: — Егерменче еллар башында Идел-Урал якларындагы ачлык хакында уйланганыгыз бармы?

— Бар...— диде Абдулла Юсупов.— Туганнарым ачлык елны кырылып беттеләр минем. Коточкыч вакыт иде...

— Сәбәп нәрсәдә дип уйлыйсыз?

— Корылык инде... Ике ел рәттән корылык булды.

— Корылык — игенченең баш өстендә мең еллар буенча асылынып торган ялангач кылыч ул. Ачлыктан котылуның бер генә чарасы бар: игенче һәрчак алдагы елларга мая калдырып килгән. Иң авыр чакларда да кагылмаган ул аңа. Мая — киләчәк, мая — яшәү дигән сүз. Ә егерменче елда игенче өстенә ач үлем ябырылып килгәндә, хөкүмәт нишли? — Айхенвальд соравына җавап та бирде.— 1920 елда Урта Идел төбәкләреннән кырык миллион пот ашлык хәзерләнә... Яшермичә әйтсәк, крестьяннан тартып, талап алынган ашлык. Тарих икән тарих булсын, ачыктан-ачык язарга кирәк. Алдагы еллар өчен сабак булыр. Илгә, нәкъ шул төбәктә яшәгән халык өстенә ябырылып ачлык килгән көннәрдә Татарстанга ун миллион йөз егерме мең пот продразверстка җиткерелә. Сәхипгәрәй Сәетгалиев моны унбиш миллион дүрт йөз мең потка җиткереп үти. Инде көз көне үк республика ишегең ачлык шакый башлый. Җитәкчеләр һаман продразверстка «үтәп» мәш киләләр. Кашаф Мохтаров — Халык комиссарлары советы рәисе дөнья революциясе хакында лаф ора. Губчека рәисе Денисов халыктан мәҗбүри рәвештә талап, җылы киемнәр җыю хакында фәрман бирә. Республикада

мең биш йөз вәкил халыкның соңгы икмәген талап җыю белән шөгыльләнә, берничә ревтрибунал эшләп тора. Һәр авылга разверстка планы җиткерелә һәм планның үтәлеше өчен авыл коллектив рәвештә җавап бирә, план үтәлмәгән очракта, авылга продотряд, халык телендәгечә «обжор команда» кертелә. Халык каршы килә, әмма мондый чуалышлар хәрби частьлар ярдәме белән рәхимсез бастырыла. Вольфович бу фактларны читләтеп үтмәкче була...

— Ни өчен? — дип, үзе дә сизмәстән сорап куйды Әхмәтсафа.— Чирен яшергән үлгән. Җан өшетерлек нәрсәләр ич болар.

— Мине дә шушы сорау борчый — ни өчен яшереп маташырга? 1920 елның 30 сентябрендә Халык комиссарлары советының беренче утырышында «продразверстка үтәү хакында Татреспублика халкына мөрәҗәгать» кабул итү мәсьәләсе күтәрелә,— дип, үзендә булган мәгълүматларны тыңлаучыларга «түгә» бирде Айхенвальд.— «Үз халкымны талыйсым юк»,— дип, мөрәҗәгатькә Шамил Усманов кул куймый. Җир эшләре буенча халык комиссары Юныс Вәлиди «Мәскәү куштаннары, милләтне сатучылар» белән хезмәттәшлек итәргә җыенмавын белдерә. 1921 елның кыш айларында ук ачлыктан меңәрләп кырыла халык. Адәм ашау фактлары күзәтелә, мәче, эт, кумак ашау инде беркемне дә гаҗәпләндерми.

— Республикага күрә торып ачлык китергән җитәкчеләр җавап тоткандыр бит Мәскәү каршысында? — диде Абдулла Юсупов. Ул инде ачлык хәлләрен үз башыннан кичергән кеше, монда сөйләнгән һәрнәрсәне йөрәге аша үткәреп, әрнеп утыра иде.

— Җитәкчеләргә ни булсын? Алар судан коры чыгалар. Сәетгалиевне азык-төлек хәзерләүдәге «уңышлары» өчен Мәскәү алтын сәгать белән бүләкли һәм ачлык котырынган 1921 елда ул Казаннан чыгып ычкына. Мәскәүдән килгән азык-төлек халык комиссары Алексей Изюмов та 1921 елда республикадан сыза, банк-сәүдә хезмәткәре булып Мәскәүдә эшли башлый. Фәкать 1921 елның җәй айларында гына, халык авыллап-авыллап кырыла башлагач кына, совет хөкүмәте Татарстанга аз-маз ярдәм күрсәтә башлый.

— Әгәр чит илләр ярдәм итмәсә, беткән идек инде,— дип куйды Абдулла.— Җәл, иртәрәк булмады ул ярдәм.

— Әйе, бәхеткә каршы, чит илләрдән ярдәм шактый сизелерлек була. Шунсыз бүгенге Татреспубликаданиләр булып бетәр иде — билгесез,— дип сүзен тәмамлады Айхенвальд.

Түгәрәк әгъзалары үткән дәвердәге авырлыкларны җаннары аша кичереп утырганда, Фатыйх Сәгыйтовның шыксыз тавышы тынлыкны бозды:

— Иптәш Айхенвальд, сез дөрес юлдан бармыйсыз! — диде ул, урыныннан сикереп торып.— 1921 елгы ачлык — ил өстенә төшкән авыр сынау, афәт иде. Корылык булмаса, ачлык та булмас иде. Бөтен гаепне Татарстанның партия, совет җитәкчелегенә өеп калдырмакчы буласыз. Ә бу сарык бәрәннәре сез сөйләгәннәрдән зур ачыш ясап утыралар менә. Шундый җитәкчеләр булмаса, ачлыктан котылып калган булыр идек, дип уйлап утыралар инде үзләренчә. Сезнең максат — Татарстан җитәкчеләренә яла ягу һәм мондый сарыклар өере алдында максатыгызга ирешәсез дә! Чынын әйткәндә, Татарстанның яңа тарихын язуда үзегезне катнаштырмаган галимнәрдән үч алмакчы буласыз. Дөрес эшләгәннәр! — дип, дуамалланып, аудиториядән чыгып китте.

— Сәгыйтов үз сүзен әйткән уңайга хаклыкка ирештем дип уйлый. Минем фикер белән килешмәве өчен аны гаепли алмыйм, әмма бүтәннәрне тыңларга теләмәвен һич төшенмим,— диде Айхенвальд, шулай ук яшьләрчә җилкенеп.— Полемикадан качмыйбыз, безнең Вольфович белән бәхәсләргә дә шаһит сез, әмма бәхәстә каршы якны мыскыл итү, аның дәлилләрен тыңламау яки төгәл әйткән фикерне кире ягы белән әйләндереп, аны имгәтү, гарипләндерү һич дөрес түгел. Кызганычка каршы, Сәгыйтов шул юлдан бара. Аны күзәтеп торам да, хәйран калам, ТКУ күләмендә нинди бәхәс кабынса, ул шунда һәрнәрсәдә үзен белгеч дип хис итә һәм ахыргы хакыйкатьне ул гына әйтергә тиеш дип уйлый. Илгә яңа кадрлар, яңача фикер йөртә алырлык гыйлем ияләре әзерлибез дип мактанабыз. Асылда, еш кына, Сәгыйтов ишеләрне әвәләп бирәбез. Алар киләчәктә ни кылырлар, ни күрсәтерләр — уйлавы да куркыныч. Бәхәс турында фән бар — эриэстика дип атала. Моназара кылу сәнгате. Бәхәстә күгәргән тавыш белән түгел, акыл, зиһен һәм белем белән җиңәргә кирәк.

— Акыллы егет ул Сәгыйтов,— диде Абдулла, нигәдер Фатыйхны яклыйсы килеп.— Кызып китәргә һәвәслеге дә булмаса...

— Кемдер әйткән: акыллы булу белемле булу дигән сүз түгел әле. Белемле һәм тәрбияле булу да икесе ике нәрсә. Бүгенге вазгыятьтә наданлык һәр җирдә чабудан килеп тота.— Айхенвальд Мәскәүдә кызыл профессорлар институтында укыганда еш кузгалган бәхәскә килеп тукталды.— Ил белән революционерлар идарә итәргә тиешме, әллә дилбегәне белемле, хуҗалык эшләрендә тәҗрибә туплаган кешеләр кулына тапшыру кирәкме? — диде ул һәм, башкаларга сорау барып җиткәнче, җавап та биреп өлгерде.— Әлбәттә, революцион романтизм чоры үтә дә китә, ә идарә итү, хуҗалык эшләре — мәңгелек. Белемле кешегә кимсетеп карау,

ышанмаучылык Рәсәйнең гомерлек чире. Бу чир революцион романтикларга, һәртөрле энтузиастларга да хас. Әлеге авыру бик тиз совет җәмгыятенә дә үтеп керде. Белемнең кирәк икәнлеген исбат итүгә киткән көч — исрафка сарыф ителгән җегәр, энергия ул. Шунысы кызганыч. Белексезлек харап итәчәк безне.— Айхенвальд Сәгыйтов ярым ачык калдырган ишекне барып япты. Сүзен дәвам итте.— Мин сезгә Татреспубликадагы ачлык һәм аның сәбәпләре хакында сөйлим икән, анда уйлап чыгарылган бер генә нәрсә дә юк. Сез — булачак җитәкчеләр, ил белән идарә итү, әлбәттә, киләчәктә сезнең кулда булачак. Әгәр совет җәмгыяте төзелешендәге кайбер хаталарны, ә бу очракта сүз сабак алу мәҗбүри булган хәл — миллионлаган совет гражданнарын теге дөньяга алып киткән ачлык сәбәпләрен ачыклау хакында барды, искә алмыйбыз, санга сукмыйбыз икән — киләчәк аяныч булачак. Тарих кабатлана, диләр. Мондый тарих исә кабатланырга тиеш түгел.

* * *

Кайнарланып үткән түгәрәк утырышларына тиздән нокта куелыр дип беркем дә уйламый иде. Сүз ирегe, фикер хөрлеге яшәгән Айхенвальд түгәрәге үтәсе көнне Әхмәтсафа аерым бер җилкенү белән көтеп ала. Монда үз сүзеңне ишеттерергә мөмкин, кирәк икән бәхәс куертып та җибәрергә була. Яшьләрнең очынуы Айхенвальдка да ошый, ул аларны кыздырып җибәрергә җай гына эзли. Бер кызып китсәләр, студентларның авызын тиз генә томалармын димә.

Менә бүген дә бәхәс куерып килә.

Фатыйх Сәгыйтов, теге көнне ишекне шапылдатып ябып чыгып китүен онытып, бүгенге утырышка беренчеләрдән булып килде. Совет хакимиятенең икътисадый нигезләрен барлаганда, көтмәгәндә яңа икътисадый сәясәтнең хуҗалык итәргә кулай булмавын расларга тотынды.

— НЭП елларында совет хуҗалыгы тәмам йончыды, эздән чыкты,— дип сөйли башлады ул, үзенә хас катгыйлек белән.— Уйлап кына карагыз, тигезлек, җир, ирек шигарьләре белән революция ясаган илдә, биш-алты ел үтмәде, крестьян ни хәлдә калды? Күтәрәмгә калдырды илне НЭП! Тигезләндек тә кебек, ирек тә алдык, җир күпме кирәк бездә, ә икътисадый бөтенлек юк. НЭП касәфәте инде.

— Яңа икътисадый сәясәт аркасында гына авылга җан иңде,— дип, аңа каршы төште Әхмәтсафа. Үткән елгы түгәрәкләрдә Сәгыйтов, чәчрәп чыгып, НЭПның бүгенге авыл өчен никадәр әһәмиятле һәм вакытлы чара булуы турында нотыклар сөйләгән иде. Моны Фатыйхның үзенә дә искәр-

тәсе итте ул.— Бу хакта син үзең дә яхшы беләсең һәм НЭПны яклый да идең, һич аңлашылмый, ни өчен болай тиз үзгәрде фикерең?

Фатыйх сабакташының сүз башлавын көтеп кенә торган диярсең, тагын да дәртләнеп китте.

— Син, Дәүләтъяров, өстәл артында Бухаринның эткә ташласаң, эт иснәмәс китапка охшаган нәмәләренә борының белән кадалып утырганда, мин, бераз гына башны күтәреп, әйләнә-тирәгә күз салдым. Илдә барган үзгәрешләрне аңлау өчен монда, ТКУда диюем, хөкүмәт икмәген черетеп яту кирәкми, болай да күренеп тора, моңарчы Бухарин калыплаган идеяләрнең көле күккә очты. Партиянең унбишенче съезды карарларын өйрәнсәң, зыян итмәс иде. Син һаман Хива-Бохара якларыннан эләктереп кайткан диһкан акылы белән яшәргә маташасың. Крестьяннарның ирегән кысма, имеш. Салым сәясәте дә фәлән-фәсмәтән, имеш, крестьян сәүдәгә тартылсын, имеш... Хәер, сәүдәгәр малаеннан ни көтмәк кирәк?

Аудитория беразга тынып калды. Соңгы чорда кайбер студентларны «сәүдәгәр, мулла малае» дип гаепләүләр ешайды. Бу гаеп ташланган яшьләргә алга табан совет уку йортларында белем алуның мөмкин булмаганлыгын аңлатучы «дәлил» иде. Шушындый гаепләү белән соңгы вакытта шактый студентны укудан куып җибәрделәр. Аларның кан-яшь түгеп, кире укуга кайтырга тырышып йөрүләренә Әхмәтсафа үзе дә шаһит. Сәгыйтовның дәлилсез-нисез аны сәүдәгәр малае дип атавы астында нинди мәкер ятканын яхшы аңлый. Оренбурда, әле ТИНОда укыган чагында да ишетте ул сүзне аннан. Көнләшү галәмәте генә дисәң... ТКУда Фатыйхның һәрнәрсәдә беренче буласы килә. Башкалар аның авызына гына карап торырга тиеш. Ул шулай уйлый. Әмма дорфалыгы, тәкәбберлеге аркасында зиһен һәм зирәклектән бөтенләй үк мәхрүм булмаган егеттән күп кеше аңлы рәвештә читләшә. Үч саклый торган егет, шуңа күрә аның белән бәхәскә кермәскә тырышалар. Бәхәскә керүдән тайчанмый торган бердәнбер үҗәт булып Әхмәтсафа калып бара иде. Әле кичә кич соң гына тулай торакка кайтып: «Яшьләр клубында Хәсән Туфан белән Гадел Кутуйның иҗат кичәсен ясап маташканнар иде. Бетләрен туздырдым! «Без — шагыйрь!» дип, борыннарын күтәреп йөрмәсеннәр. Пролетариат белән крестьянга нинди шигырьләр кирәк икәнлеген сөйләп бирдем үзләренә, ул шагыйрь кисәкләрен яңадан сәхнәгә менмәслек иттем!» — дип әтәчләнеп йөргән Фатыйхка бүген тагын кемдер каршы килеп маташсын инде, җә?! Житмәсә, укытучылар алдында. Үҗәт Дәүләтъяровка ни җитми? Үҗәтлек чикне үтсә, чиргә әйләнә, дөрес инде. Моңа ничек түзсен дә Сәгыйтов, нервысы ничек чыдасын?..

— Шулай, сәүдәгәр малае дигәч, тиз шиңде Дәүләтъяров,— дип һаваланды Сәгыйтов, бәхәскә нокта куйгандай.— Бу сиңа кеше талап мал җыю түгел, без икътисадның какшамас социалистик кануннары хакында сөйлибез, ә син кем тегерմәненә су коеп маташасың? Икътисад иҗтимагый җитештерүнең объектив кануннарына буйсына, НЭПның кесә канунына түгел.

Надир Әбдершин, Әхмәтсафаның күптәнге дусты һәм авылдашы, түзмәде, урыныннан сикереп торды:

— Әхмәтсафа сәүдәгәр малае түгел! — диде кайнарланып.— Ул ятим үсте, үзенең тырышлыгы, зирәклеге аркасында гына алга юл ярып бара. Әтисе Мостафа агай авылның иң ярлы игенчеләреннән иде. Гаиләсен туйдыра алмаганга, балаларын байларга көнлекче итеп бирде, үзе айлар буе өенә кайтып керми, казакъ арасында тире-яры белән эш итеп йөрде. Хәтәр эш ул, куркыныч, авыр хезмәт. Алай да мантый алмады, яшь балаларын үги әни кулына калдырып, үлеп китте. Әхмәтсафа ятим үсте,— дип кабатлады Надир.— Нинди сәүдәгәр нәселе булсын ди. Әкият сатма инде, Фатыйх, үзең дә яхшы беләсең...

Фатыйх бу сүзләргә керфеген дә селкетмәде.

— Үзең үк әйтеп торасың тагын. Тире-яры белән эш иткән кеше сәүдәгәр булмый, кем булсын инде? — дип авызын ерды ул.— Вак сәүдәгәр, байлар белән эш йөрткән кеше, нигә яклап маташасың?

— Байлар белән эш йөртмәгән кеше юк иде ул чакта,— диде Надир, Фатыйхның белә торып Әхмәтсафага яла ягуына рәнҗеп.— Аңа калса, син үзең дә мулла малае.

Фатыйхны җен алыштырдымыни! Ул атылып урыныннан торды, Надир янына килеп басты, аның якасыннан эләктереп алып, төкерекләрен чәчә башлады:

— Тагын бер мәртәбә кабатласаң, телеңне тартып өзәм! Мин инде әллә кайчан мулла атайдан баш тартуым хакында хәбәр иттем. Моны бөтен кеше белә. Ә син... син... бетле күркә, күрәләтә алдашу юлы белән, съезд тарафыннан ныгытылган фикерләремнән ваз кичтермәкче буласыңмы? Минем юлым — партия юлы, мәсләгем — партия мәсләге. Синең ише сәүдәгәр, кулак кебекләр белән уртаклыгым юк! — Фатыйхның иреннәреннән ак күбек ургылып чыкты. Ул калтыранып урынына килеп утырды, үзе һаман тынычлана алмый.— Сәүдәгәр, кулак калдыклары кереп тулган, авыз ачып сүз әйтергә дә бирмиләр, паразитлар, идән асты кыргаяклары,— дип зәһәрен чәчә иде.

Әхмәтсафа түзмәде, урыныннан күтәрелде.

— Сәгыйтовның төкерек чәчүеннән шыр җибәреп утырыр чаклар үтте,— диде ул, тыныч, әмма беренче сүзләрен-

нән үк башкаларны җәлеп итәрлек нык тавыш белән.— Мин аның кебек сәяси флюгер була алмыйм. Партия карарларын ничек теләсәм, шулай бозып аңлата да алмыйм. Әйе, соңгы чорда партиядә бәхәсләр берьяклырак була башлады. Бухаринчылар дигән сүз кирәгеннән артык куертыла. Ә бит иптәш Сталин Бухаринны «социализм төзелешенең прорабы» дип атады. Әле үткән елларда гына фикер аерымлыгы да сизелми иде. Партия сафларының ныклыгына сокланып яши идек.

— Сәяси сукыр! — дип җикеренде Сәгыйтов.— Надан сүз сөйләп, тавык көлдермә, ичмаса. Партиядә бернинди бәхәс, аерымлану да юк. Сүз — тиз арада коллективлаштыруны тәгәлләү, промышленность үсешен тиешле дәрәҗәгә җиткерү хакында бара. Солтангалиевче икәнлегеңне беләбез, кирегә сукалап торма, яме.

— Солтангалиев мәсьәләсенә килгәндә, кызганычка каршы, мин аның белән таныш түгел, карашларын да ныклап белеп бетермим, аны партия гафу иткән иде инде...

— Бүре баласын бүреккә салсаң да, урманга карый, Дәүләтъяров. Үзең кебек инде. Сезнең ишеләргә тел белән аңлатып була торганмы? Солтангалиевне дә күпме иркәләделәр, башыннан сыйпап кына йөрттеләр. Нәтиҗәсе — Солтангалиев йөрде-йөрде дә, һаман шул милләтчелек сазлыгына кереп чумды. Аның иярченнәре Мидхәт Борындыков белән Мәхмүт Бөдәйлине бик дөрес кулга алдылар. Аларны таш ваттырып кына акылга утыртып була.

— Газеталарда «Утызтугызның хаты» басылып чыкты. Җитди сүзләр бар анда. Солтангалиевне аклауны сорыйлар безнең зыялыларыбыз,— дип, бәхәскә кушыласы итте Абдулла Юсупов. Ул мондый бәхәсләрдән читтәрәк торырга ярата, шулай да бәхәсне кыздырып җибәрергә аңа куш, каян чамалап ала, инде сүз көрәштерү басыла башлый дигәндә, ике-өч сүз ыргытырга өлгерә, сүз янә куерып китә.

— Һе, надан,— диде ачы тавыш белән Сәгыйтов.— Ул «утызтугыз» дигәнең ничәгә калгандыр. Хатка кул куйган сәяси куштаннар инде үзләре үк бу эшләреннән баш тарталар — комиссар Шамил Усманов беренче булып Солтангалиевтән ваз кичте. Башкалары да озакламас...

Айхенвальд, сүзнең аерым шәхесләр тирәсендә әйләнә башлавын күреп, түзмәде, шәкертләре чуалтып бетергән җеп очын эләктереп алмак булды:

— Ну, егетләр, гайбәт сатарга гына булсын сезгә. Бу сүзләр бит, ачуыгыз килмәсен, гайбәт югарылыгында гына. Башта бер-берегезне пычратып азапландыгыз, хәзер милли зыялыларыгызга ябыштыгыз. Сезнең өчен абруй да, табынган кешеләрегез дә юк. Сүзгә керешсәгез, барысын рәттән буярга кирәк. Каян өйрәндегез бу һөнәргә?

— Табынган кешебез — иптәш Сталин, аның сүзе иң дөресе. «Большевиклар ала алмаган крепостьлар юк!» Мин үземне большевик дип саныйм, шуңа күрә вак буржуаз тәгълиматка, мещанлыкка, һәртөрле аумакайлыкка рәхимсез сугыш ачам,— дип җилкенде Сәгыйтов.

— Ярый, шулай да булсын, без иптәш Дәүләтъяровны тыңлыйк әле. Карап-карап торам да, тагын бер карап алам дигәндәй, бу мәсьәлә белән ике кеше — ул һәм Сәгыйтов кына кызыксына кебек.

Бу сүзләргә Сәгыйтовның үтә дә кәефе килеп, түшләрен киереп, як-ягына масаюлы караш ташлап алды.

Әхмәтсафа алдында яткан конспектка күз дә салмый сүзен дәвам итте:

— Ачыклап китим, 1927 елның декабрендә үткән унбишенче съезд коллективизацияне бердәнбер һәм иң дөрес юл дип тапмады бит. Барлык төр кооперацияләрне дә хуплаган карар кабул итте. Аннан соң елдан артык вакыт үтте, дөресен әйтәм, мин үзем дә коллективлаштыруның мөһимлеген таныйм. Яңа техника үсешендә могҗиза булган электрофикация аша коллективлаштыруга йөз тоту — төп юлларның берсе шул. Шунсын да таныйм, аерым бер кооперация төренә өстенлек бирелмәде. Съезд Бухарин, Рыков иптәшләр алга сөргән һәм нәкъ соңгы чорда зур бәхәс куптарган нәрсә — индустриализация белән авыл хуҗалыгы үсешенә финанс өлеше кертүнең дөрес бүленешен яклады. Моңа иптәш Сталин үзе дә каршы килмәде. Җитмәсә, 1927 елда барлык крестьяннарның өчтән бере инде кооперацияләргә берләшкән иде. Димәк, халык авылда бердәмләшеп эшләүгә, яшәүгә каршы түгел. Халык шушы юлга тартыла икән, санлашмый булмый.

Сәгыйтов тагын түзмәде.

— Ташла инде халыкны изгеләштереп, аннан әүлия ясауны! Халык бүген болай, иртәгә тегеләй. Аңа дөрес установка бирү кирәк һәм вәссәлам.

Айхенвальд, килешмәгәнен белдереп, башын чайкап куйды.

— Беркөнне Дәүләтъяров Маркның акыллы сүзләрен хәтердә яңартты. Кабатлау зыян итмәс: әгәр без идеяне тормышка ашыручыларның мәнфәгатьләрен санга сукмыйбыз икән, ул идея беркайчан да чынга ашмаячак.

Әхмәтсафа алдында яткан кәгазьләренә күз салып алган булды. Студентларның аны ышанып, бирелеп тыңлауларын чамалап алган иде инде ул. Тыңлаучыларның барысы да диярлек авыл балалары, авылга кагылышлы һәр сүз аларның җаннары аша үтә, Әхмәтсафаның сүзләре йөрәкләренә сары май булып ята.

— Авылда куллану кооперациясе үсеш юлында иде, кус-

тарь-промышленность кооперациясе дә җанланып килә. Һәркайсыбызның күз алдында, авыл белән шәһәр арасында бәйләнеш ныгый бара. Шуңа күрә мин иптәш Бухаринның: «Индустриализацияне гамәлгә ашырганда крестьяннарның мәнфәгатьләрен һәрдаим истә тотарга кирәк»,— дигән сүзләрен яклап киләм. Бу һич тә сәяси сукырлык яки кирелек түгел.

— Син сәяси күрәкараучыга әйләнеп барасың! — дип, аны бүлдерде Сәгыйтов.— Мең тугыз йөз егерме җиденче-егерме сигезенче елларда икмәк хәзерләү кампаниясе нинди хәлгә төште? Авыл үз мәнфәгатен кайгыртып, шәһәрне ачлык ягасына китереп терәде. Ә син, бәйләнеш ныгый дип, кеше башын катырасың!

Сәгыйтовка җавап кайтарып торуны кирәк санамады Әхмәтсафа.

— Ә кулакларга мөнәсәбәтегез? — дип сораган булды Айхенвальд чыгыш ясаучыдан.

— Кырып себерергә! — диде Сәгыйтов.

— Монда эш катлаулырак,— диде Әхмәтсафа, нигәдер тавышын баса төшеп.— Унбишенче съезд карарларында ачыктан-ачык күренә — анда сүз кулакны физик юк итү турында бармый. Икътисадый ысуллар кулланып, аларның эксплуататорлык мөмкинлекләрен чикләүне тормышка ашыру күз уңында тотылды. Кулакны талап, хәерче хәленә төшерү аяныч нәтиҗәгә китерә.

— Син, димәк, иптәш Молотов кул куйган 1928 елның беренче март хатын вакытсызрак дип табасың? Анда бит сүз нәкъ менә кулакны тамырдан юк итү хакында бара.

— Партия җитәкчелегенә каршы килә алмыйм...

— Килеп кара!

Моны Сәгыйтов әйтте.

— Иптәш Молотовның «Урындагы партия оешмаларында чәчүлек җирләрен арттыру һәм крестьян хуҗалыкларын коллективлаштыруны тизләтү» турындагы хатында «партия, совет органнарының эше коллективлаштыру нәтиҗәләре нигезендә бәяләнә» диелгән. Бу съезд карарларына каршы килә, минем фикерем шундый.

— Әт-тә-тә, акыллы баш табылды! — Сәгыйтов янә урыныннан кузгалды.— Ни өчен мондый каршылык килеп чыга дип уйламадыңмы, миеңне самавыр күгәрегә баскан нәстәкәй?! Синдә булган кәгазьләр миндә дә бар ул! — диде ул эре генә.— Менә тыңлап кара. Син яклап маташкан кулакларның «тырышлыгы» белән үткән елда икмәк хәзерләү кампаниясе өзелде. Ил ачлык куркынычы алдында калды. Син, Дәүләтъяров, иптәш Сталинның: «Бездә эчке дошманнар бар, бездә тышкы дошманнар бар. Бу хакта бер генә

минутка да онытмаска кирәк!» — дигән даһи сүзләрен санга сукмыйсың.

— Бу бит конкрет сөйләшү түгел...

— Нәрсә? Юлбашчының сүзләре конкрет түгелме? — дип, күзләрен акайтты Сәгыйтов.

— Иптәш Сталин бик дөрес күрсәтә. Яңа җәмгыять төзегәндә, аңа каршы көчләр табыла. Куелган сорауга конкрет җавап бирмәдең дип кенә әйтәсем килде.— Әхмәтсафа үзен сәяси сукырлыкта гаепләүләрен теләми иде. Әмма моңарчы илдә хөкем сөргән, соңгы чорда «бухаринчылык» дип мөһер сугылган карашларыннан тиз генә ваз да кичә алмый. Аның инануынча, ул идеяләр дөрес иде. Соңгы чорда ниндидер аңлашылмаучылык булды, партия сәясәте үзгәреп, үткән чорда аңга сеңдерелгән идеяләрне көч, акыл сарыф итми бер селтәнүдә кире кага башлау аңлашылып җитми иде, ягъни бу гамәлдән үзе утырган ботакка балта чабу шикеллерәк бер нәрсә килеп чыккан иде.— Икмәк хәзерләүдә ел саен бер кыенлык туа тора. Шулай да егерме беренче елдагы ачлык сәбәпләрен искә алып эш итү нәтиҗәсендә, фаҗига кабатланмады. Узган ел авыл икмәкне башка елларга караганда аз җыйнап алды. Хәлле крестьян шушы хәлдән файдаланып калырга маташты. Илдә икмәк аз булган саен, аңа бәя арта бара. Кулакның исәбе гади иде. Илне ачлык чигенә җиткереп, шуннан байтак керем алырга җыенган кулакның гамәлен мин дә хупламыйм.

— Техник культуралар яхшы уңыш бирде,— дип сүз кыстырып алды Айхенвальд.

— Әйе, икмәге булганнар, хөкүмәтнең сатып алу бәяләрен арттырганын көтеп, сатуны кичектерә килделәр. Техник культура хисабына яшәргә була иде бераз. Хәлсез хуҗалыклар исә икмәкләрен көз көне үк хөкүмәткә арзан бәягә сатып бетерде һәм яз көне, өч бәя артык түләп, чәчүлек орлыгы сатып алырга мәҗбүр булды.

— Терлекчелек артуга йөз тотты. Еллык артым биш процент,— дип, Айхенвальд шәкертенең дәлилләрен раславын сиздереп куйды.—Сатуга чыкмаган икмәк терлек асрауга тотылды.

— Дөрес әйтәсез, терлекләргә дә азык кирәк. Ләкин хөкүмәт шушы хәлдә дә индустриализация темпларын киметү ягын карамады. Бөтен авырлык авыл өстенә ишелде, ягъни үзе дә ярым ач хәлдә ул зур төзелеш мәйданына әверелгән илне тартып барырга мәҗбүр булды. Нишләргә кала? Бер генә юл — крестьяннардан икмәкне тартып ала башладылар. Мәхкәмәгә эш артты. РСФСР җинаять кодексының 58–10 статьясы, ягъни контрреволюцион агитацияләүдә гаепләп кулга алулар ешайды. НЭПка, фактик яктан килгәндә, нокта куелды.

— Синең үзеңә 58–10 статьясын кулланырга кирәк,— дип ысылдады Сәгыйтов.— Җаның-тәнең белән уң оппортунистларны яклыйсың. Тиреӊ җыртылып чыкмаса ярар иде дип куркып утырам менә.

— Бүгенге вазгыять хакында фикер йөртеп, Ленинның социализм һәм кооперация төзү планыннан тайпылышлар булуын гына күрсәттем.

Айхенвальд янә сүзгә кушылып алды.

— Дәүләтъяров үз фикерен иптәш Бухаринның «Икътисадый язмалары»на нигезләп шәрехләде. Дөрес эшләде дип уйлыйм. Чынбарлыкка дөрес бәя бирелде. Синең шикелле, Сәгыйтов, кемнәрнеңдер ниндидер гаепләрен санап утырып кына социализм төзеп булмый.

— Киләчәктә сугылачак кирпечләр белән бүген үк фабрика төзи башларга мөмкин түгел. Әүвәл кирпечне сугып, төзелеш мәйданына китерергә кирәк, аннан гына төзи башларга була. Беренче бишьеллык планын тормышка ашырганда мондый кимчелекләр исәпкә алынса иде дигән теләктән генә чыгып сөйлим.— Әхмәтсафа, сүзе беткәнгә санап, урынына утырмакчы булды.

— Елап та җибәр инде, ышанырлар,— диде Сәгыйтов, яшерен тантана белән.— Статья дип сүз кузгаткач, Дәүләтъяров ничек шиңде! Бик телең кычыткач, аферист Бухарин астыртын ният белән шушы егерме тугызынчы елның гыйнварында «Правда» газетасын пычратып баскан Ленинның «Сәяси васыятен» дә яттан сөйләп чык. Декламация сөйләргә оста бит син.

— Илнең җитәкчеләре арасындагы каршылыкларга кысыласым килми. Минем эшем түгел бу. Фикеремне кабатлап кына әйтәм — авылда дөрес сәясәт үткәрелмәсә, хәлләр аяныч булырга мөмкин...

Әлеге бәхәс түгәрәкнең соңгы утырышы булды. Вольфовичка кемдер әләкләгәнме, әллә үзе шундый фикергә килгәнме, инде ВКП(б) тарафыннан тар-мар ителгән Бухарин идеяләре нигезендә Айхенвальдның һаман бәхәсләр оештырып ятуын өнәмичә, ул түгәрәк эшен тыйды...

...Әхмәтсафа, уйларыннан айнып, әрнү катыш көлемсерәп куйды. Дөнья куласа, әйләнә дә бер баса, ди, инде хәзер үзе авылда совет тәртипләре урнаштып йөри менә. Һәрхәлдә, шушы эшне йөкләде аңа кантком. Үзе яклаган хәлле крестьян хуҗалыгын туздырырга бара. Йорт хуҗасын кулга алгач, ул нигездән ни каласы билгеле инде. Әтисе вафатыннан соң үзләренең нигезе бөтенләй юкка чыга язды. Ярый әле Гомәрхан исән-имин кайтты сугыштан. Хәлле крестьяннарга карата кантком ике генә гамәлне белә: кулга алырга,

мөлкәтен туздырырга. Кая монда крестьян мәнфәгате, кая монда Бухарин идеяләре. Юлга чыгып китәр алдыннан Филиппов кулакларны физик юк итү хакында мең тугыз йөз егерме тугызынчы елның җәй аенда җирле партия оешмаларына җибәрелгән Молотов хатын кат-кат исләренә төшереп алды:

— Сез авыллардан җыеп китерәчәк кулаклар өч төркемгә, ягъни категориягә бүленә,— диде ул, белдекле кыяфәт белән. Сүзнең мөһимлеген искәрткәндәй, маңгаена бәреп чыккан тирне кул аркасы белән сөртеп алды. Соңгы вакытларда җүнле-башлы йокы күрмәгәнгә, аның йөзе агарып, сулып калган иде. Таң алдыннан гына кантком утырышы бетүгә карамастан, иртүк Әмәкәй авылына китүче төркемне озатырга килеп җиткән, аларга инструкция биреп, өйрәтеп җибәрүне үзенең бурычы итеп санаган иде.— Беренче категория — контрреволюцион актив, советка, колхозга каршы чыгышлар оештырган яки бу эшкә турыдан-туры катнашкан кулаклар һәм аларның куштаннары. Соңгы вакытта күреп-ишетеп беләсез, Әлмәт, Буа кантоннарында кулаклар коткысы аркасында халык белән кызыл гаскәриләр арасында кораллы бәрелешләр булып алды. Кулакларны җир йөзеннән себереп түкмичә торып, «Коллективлаштыруны — йөз процент!» дигән социалистик йөкләмәбезне үти, иптәш Сталинның «Бөек борылышлар елы» дигән мәкаләсенә лаеклы җавап бирә алмаячакбыз. Иптәш Сталинның шушы мәкаләсенә җавап итү йөзеннән генә дә мин бөтен кулакларны җир йөзеннән себереп түгәр идем. Тамырлары корырга тиеш аларның! Тә-әк... Беренче категория — гаиләләре белән Себергә сөреләчәк,— дип, мәгънәле караш ташлады Филиппов Шәмтиев ягына.— Иптәш Шәмтиев, аңлашылдымы?!

— Сөрәчәкбез, иптәш Филиппов, этләре-песиләре дә калмас, нигезләрен туздырачакбыз.

— Дөрес әйтмәдең, Шәмтиев. Бернәрсәне дә туздырмагыз. Әйберләрен конфисковать итеп, колхозга тапшырырга. Йортларын совет учреждениеләре итәргә, ярлы колхозчыларга бүлеп бирергә. Аңлашылдымы?

— Ялгышлык китте, иптәш Филиппов, ялгыш ычкындырдым. Сез әйткәнчә эшләрбез... Туздырмабыз, башкаларга өләшербез.

Филиппов, җаваптан канәгатьләнеп, аңлатуын дәвам итте:

— Эре кулакларны, күмәкләшүне өнәмәүчеләрне, эшкә аяк чалучыларны кулга алып, гаиләләре белән ерак районнарга сөрү каралган. Болары икенче категориягә керәләр. Тә-әк... Өченче категория дигәннәре — вак кулак, кулак тегермәненә су коючылар була инде. Шушы өч төркемгә кергән контрреволюцион элементларны кулга алып, Минзә-

лә төрмәсенә китереп ябу эше йөкләнә сезгә. Авыл активистларына да эш җитәрлек. ОГПУ ярдәме белән кулак гаиләләрен өч көн вакыт эчендә авылдан сөреп, әйберләренә кадәр конфисковать итәргә. Җаваплы — Шәмтиев.

— Эшләрбез, иптәш Филиппов, инә-төймәләренә кадәр конфисковать итәрбез. Үзләрен кулга алып...

— Җитте, Шәмтиев, кайткач сөйләрсең. Хәзер юлга! Сак булыгыз, каршылык очраса, ике дә уйлап тормый, корал кулланыгыз.

Сүзгә ОГПУ башлыгы да кушылды:

— Кулга алынганнар нидер сизенеп, тавыш-мазар күтәрергә тиеш түгел. Минзәләгә барып, бер кәгазьгә кул куеп кына кайтасыз дияргә кирәк булыр. Әмәкәй зур авыл, ярминкәле, базарлы авыл. Төрле яктан җыелган әтрәк-әләм күп булыр. Тирә-як авылларга хәбәр салып өлгермәсеннәр...

...Кайчан гына Матвеевкада җылынып чykканнар иде. Аякларга суык үрмәли башлады. Бигрәк тә ат өстендәге җайдакларга кыен. Шуңа күрәдерме төркем башлыгы, Әтрәкле дигән авылга җиткәч, тукталыш ясарга боерды.

Әтрәкледән караңгы төшә башлагач кына кузгалып, Әмәкәй дигән ерак авылга төн уртасында гына килеп керделәр. Колакта исә Филипповның каты тавышы:

— Контроль саннар... Үтәлергә тиеш. Арттырып үтәрбез...

* * *

Алар тукталган йорт — каравыл өе. Бер үк вакытта авыл советы бинасы да, ызба-читальня ролен дә үти икән. Минзәлә «кунакларын» ике кеше каршы алды. Авыл советы рәисе, кызыл йөзле, сары керфекле Сабиров һәм ак чырайлы, тавышын кайдандыр тирәннән кысып чыгарып сөйләшүче Габитов — партия ячейкасы секретаре.

Бераз юангач, кечкенә киңәшмә үткәреп алдылар. Авыл волость үзәге булса да, волком җитәкчеләре якын-тирәдәге авылларда советка, коллективлаштыруга каршы кешеләрне ачыклау белән мәшгульләр, канткомнан һәр волостька, волком тарафыннан исә һәр авылга контроль саннар җиткерелгән, шушы саннарның үтәлешенә карап, партия ячейкасы, авыл советы эшенә бәя бирелә. Волком, авыл активлары көн-төн чабалар, әмма канткомнан төшерелгән саннарны үтәп өлгерә алмыйлар икән.

Каршылаучылар арасында волкомнан вәкил булмавына Шәмтиев, пошынып:

— Җаваплылыктан качалар, понимаешь! — дип сукранып алды. — Имеш, авыл советы эшенә тыгылмыйлар. Ничава, кайткач, Филипповка әйтеп, җоннарыгызны туздыртам...

Үзенә артык игътибар итүче булмагач, Шәмтиев тынды. Монда кем башлык икәне ярылып ята — Сабиров белән Габитов ОГПУ кешеләре тирәсендә бөтереләләр иде.

Авылга төн үзәге җиткәндә, күзгә төртсәң күренмәслек караңгыда килеп кергәнлектән, Әхмәтсафа авыл белән аз гына да таныша алмады, әмма якын-тирәдә Әмәкәй белән тиңләшерлек авыллар юк дип кисәткәннәр иде Минзәләдә.

— Әгәр дә уйламыйча, тиешле хәзерлек күрмичә эш башласагыз, кайбер кантоннардагы хәлләр монда да кабатланырга бик мөмкин,— дигән иде Филиппов, юлга кузгалганда.— Кулакларны, муллаларны халык чолгап алып, авылдан алып китәргә комачаулыйлар. ОГПУ вәкилләрен үзләрен тотак итеп алалар. Совет вәкилләрен өйләренә үткәрмиләр. Каршылык күрсәтүче табылса, җебеп, каушап калмагыз, нагайка-чыбыркы тоткан кулларыгыз калтырамасын, кирәк булса, корал кулланырга да тайчанмагыз — сез дөрес юлда, кылган барлык гамәлләрегез акланачак, чөнки сез халык өчен, ил өчен көрәшнең иң авыр участогында бүген,— дип җилкендереп калган иде.

Шәмтиев шушы ук сүзләрне Габитов белән Сабировка да кабатлады. Сабиров урынында утырып тора алмый, тынгысыз кеше, башта Минзәләдән килгән вәкилләрнең атларын урнаштырып чабулап йөрде, аннан вәкилләрнең үзләренең тамакларын туйдырып мәш килде. Габитов исә Шәмтиевнең сөйләгәннәрен төче елмаю белән тыңлап торды-торды да, тавышын кысып кына, тагын каядыр чыгып китәргә җыенган Сабировка эндәште:

— Иптә-әш Сабиров, исемлекне бир әле-е... Иптә-әш Шәмтиев белән киңәшеп алыйк, дим. Нәрсә җитми-и, нәрсә арты-ык дигәндәй...

— Бар исемлек, бар ул. Инде өч көн кесәдә саклап тотам...

Сабиров, ара-тирә гөлт-гөлт итеп ялкын чөеп алса да, гамәлдә сүрән янган куыклы лампа мәлҗерәп утырган өстәл янына килеп, исемлек язылган кәгазьне җәеп салды.

— Әйе, исемлек ба-ар ул...— дип төчеләнде Габитов.— Бер генә «дошман элемент» та төшеп калмады. Тырыштык инде, тырыштык. Бәй, соң... кулдан килгәннең барысын да эшләдек, әйеме, иптәш Сабиров? Шуны да эшләмәскә ни-и...

— Йокы-мазар күргән юк бу арада, гел исемлек барлап утыру булды инде.— Сабировның тынгысыз карашы Дәүләтъяровка төртелеп туктап калды. Чыннан да, үтә тырышлык күрсәтүләре хак иде, хәлне кантком вәкилләренә төшендереп, теләктәшлек табасы килә иде.— Нидер сизенә кулак, авылда кот калмады бу көннәрдә, әмма без алай капчыкны төбеннән тотып селкемәдек...

— Сизенмичә, иптә-әш Сабиров, кайткач хатыныңа ычкындыргалый торгансыңдыр. Хатын колагына кергән сүз авыздан чыкмый калмый ул! — Габитов, аерым бер ләззәтле мизгелләр кичереп, исемлекне укый башлады. Ара-тирә аңлатма биреп тә бара иде. — Исемлеккә, иптәш Шәмтиев, дүрт мәчетнең дә муллаларын, мәзиннәрен керттек. Түбән оч мәчеттән — Бакир мулла, Фазыл мулла, Шәрәфетдин мулла... Бусы-сы Түбән оч мәчете-ете... Урта мәчеттән — Шәйхелислам мулла, Мирзасалих мулла, Нурлыгаян мулла-а... Менә бусы-сы Урта мәче-ет... Югары оч мәчетеннән — Әхмәтшакир мулла, Мирзаян мулла, Әхмәтзакир мулла-а... Менә бусы-сы Югары оч мәчете-е. Манарасыз мәче-ет... Бусы-сы яңа мәчет була инде-е... Анда бер Хөснетдин хәзрәт кенә гыйбадәт эшләрен алып барды.

— Габитов төгәл кеше ул! Исемлекне бик җентекләп төзеде,— диде Сабиров, җитди кыяфәт белән.

— Бар, бар, монда барысы да бар, иптәш Шәмтиев. Категорияләрен шапылдатып сугып чыгыйммы соң? Бездән калмасын дигәндә-әй...— Габитов, куштанланып, кулына каләм алды.

— Озак сузабыз! — Шәмтиев тынычсызлана башлады. Ишек төбендә утырган ОГПУ вәкиленә шөбһәле караш ташлап алды. ОГПУ вәкиле аның сүзен җөпләп баш какты.

— Ашыгырга кирәк, авылдагы күп өйгә һаман ут элеңгән килеш. Соң дип тормый халык, йокларга ашыкмый, нидер сизенгән шикелле.

— Борчылмагыз, Әмәкәй халкы бик чуар халык ул,— дип тынычландырды аларны Габитов.— Иптәш Сабиров активистларны чыгарып җибәрде инде, барысын да җилтерәтеп китереп җиткерерләр. Шым чыгаручы да булмас. Монда бит борынгыдан теләсә кайдан җыелган халык. Берсенә яманлык эшләсәң, ике як күршесе сөенеп утыра. Безнең халык шундый бит ул.

— Активистларыгыз кая соң? Күзгә-башка күренмәде.

— Һи-и,— дип, нечкә тавыш белән көлгән булды Габитов.— Аларны, өч көн шартлы тотак итеп, күршедәге Якуб бай келәтендә яткырдык. Һәркайсына задание җиткерелгән, хатыннары килеп ашатып йөрделәр. Үзләре дә ялыгып беттеләр, бичаралар. Инде бәйдән ычкынган эт шикелле кылана торганнардыр. «Әгәр үзегезгә беркетелгән кешеләрне китереп җиткермәсәгез, үзегезне тотып җибәрәбез,— дидек.— Хатыннарыгызны камчы белән ярабыз, балаларыгызны авылдан куабыз»,— дип куркыттык. Һи-и шүрләделәр, иптә-әш Шәмтиев. Кая барсыннар, безнең халык сәер куркак бит ул. Берсе өстенә өстерсәң, икенчесен ботарлап ташларга да әзер.

ОГПУ вәкиле, каравыл йортындагыларга кирәксә-кирәк-

мәсә чыгып йөрмәскә кисәтеп, чыгу ягына кузгалды. Каерып ачылган ишектән бөркелеп суык керде. ОГПУ вәкиле чыгып киткәч, Шәмтиев, үзен зур түрәгә санаган кебек, түшен киерә төште. Вәкарь рәвештә Габитовтан сорашуын дәвам итте.

— Хуш, кемнәр киләчәк инде монда? «Минзәләгә, төрмәгә алып китәргә» дип җыясызмы халыкны?

— Юк инде, иптәш Шәмтиев, без дөнья күрмәгән кешеләр түгел бит. Минзәләдән вәкилләр килгән, бер кәгазьгә кул куясыз да кайтарып җибәрәләр, дип әйтергә куштык. Әйе-е, иптәш Шәмтиев, моны гына беләбез инде без, Сабиров булса, ул да җөпләр иде сүземне.

Шәмтиев кинәт кенә Әхмәтсафаны исенә төшерде булса кирәк, аңа борылды:

— Иптәш Дәүләтъяров, менә бу исемлектәге язылган адәмнәрне тиз генә категорияләргә бүлеп яз әле!

— Категориягә? — дип аптырап сорады Әхмәтсафа. — Мин бит аларның ни үзләрен, ни кылган гамәлләрен, матди хәлләрен белмим. Моны иптәш Габитов үзе генә эшләсә инде...

Шәмтиев, ризасызлыгын белдереп, кашларын җыерды, мыгырданып алды:

— Минзәлә тиклем җирдән килеп, кул кушырып утырмассың бит. Нәрсә дә булса эшләргә кирәк.

— Миңа кушылган кадәргесе шул — мондагы хәлләр белән танышырга, тәҗрибә алырга, кайткач, хисап бирергә.

— Хисап бирүчеләр буа буарлык, эшләргә дисәң — Шәмтиев... Әйдә, Габитов, укып чык, мин, үземә язып алып, категорияләргә бүлеп чыгармын.

Габитов тырышып исемлекне укый башлады. Ара-тирә шәрехләп тә ала иде.

— Муллаларны әйттем инде, алар җәмгысы ун кеше була.

— Булсын, булсын, бер сүзекәем дә юк...

— Инде байларга, кулакларга килсәк, эш болай тора-а... Хөснелгата бай, Хәсән бай, Биктимиров Өммәткол — бик зәһәр адәм, усал, куәтле кеше бу... Инде дә килеп Шәвәлиев Гыйзетдин, Латыйпов Якуп — бай Якуп дип йөртәләр, моның уллары Гыйззәт, Габдрахман, Салих... Инде дә килеп Мөхәммәди Закиры, Суфиянов Миркасыйм, Йосыф...

Габитов укый бара, Шәмтиев, аның артыннан яза барып, һәркайсын үзенчә категорияләргә бүлгәләп бара иде. Кешеләрнең язмышына карата шундый битарафлык белән Әхмәтсафа бу дәрәҗәдә, бәлки, беренче мәртәбә очрашкандыр.

Исемлекне барлап чыккач, Шәмтиев тузына башлады.

— Нинди хәл бу? — дип җикеренде ул Габитовка. — Контроль сан җиткерелмәгән идеме сезгә? Бер кешең җитми, панимаешь!

— Җиткерелде-е... — Габитовның тавышы еламсырап чыкты бу юлы. — Тырыштык, иптә-әш Шәмтиев, кулдан килгәнчә. Авылда хәлле дигәннең барысын да җыеп тутырдык... Ничек үтәп чыкмак кирәк — егерме җиде кеше-е бит ул, егерме җиде...

— Әкият сөйләмә, Габитов! Әмәкәйнең һәр икенче кешесе мондагы өч категориянең берсенә керерлек. Кара аны, үзеңне алып китәбез, заданиене үтәмәсәң!

— Ни бит, иптәш Шәмтиев, күпләре авылны ташлап чыгып киттеләр, теге вакытта ук. Моннан алда да җыеп җибәргәләдек... Кими бит халык. Бер кеше тулмый инде, шуңа да бәйләнеп...

— Җитте, Габитов, әнә ОГПУ вәкиленә әйтеп, кул-аягыңны бәйләтеп, чанага чыгарып салдырам. Тап бер кеше!

Габитов куркынган күзләре белән ишектән кереп килүче ОГПУ вәкиленә карап алды, бертын уйланып утыргач, ниһаять, тәвәккәлләп авызын ачты.

— Менә безнең авылда Сөләйман карт бар. Бик ачы телле нәмәкәй. Әле кичә дә, ураза аенда мәчетләрне ачтырмыйсың, дип бәйләнде миңа. Ата күркә, дип мыскыл итте. Әллә соң...

— Язып куй исемлеккә! Сөләйман картмы-чуртмы, анда бер кешенең дә эше юк, контроль сан гына үтәлсен.

...Озакламый каравыл өенә халык җыела башлады. Барысының да йөзе сүрән, барысы да хәлләренең мөшкел икәнен аңлыйлар. Үзара бер-берсенә нидер әйтеп алалар да тынып калалар. Бары берсе генә гайрәт чәчеп азапланды:

— Кая, нинди кәгазьгә тамга саласы? Озаклап маташырга вакыт юк, сәхәр ашар вакыт җитә...

— Ашыкма-а, Өммәткол абзый, — диде Габитов, әүвәлгечә төче тавыш белән. — Җыелып бетсеннәр инде. Кеше саен бер амин дигәндәй, һәркайсыгызга аерым-аерым аңлатып-сөйләп тора алмый бит инде кантком вәкиле. Минзәлә тиклем җирдән юкка килмәгән.

Шәмтиев, Габитовның җавабын ошатып, баш какты. Халык җыелып беткәч, исемлек буенча барлап чыктылар. Тышкы якта, каравыл өе тирәсендә хатын-кыз, бала-чага тавышлары ишетелә башлады. Күрәсең, алар да хәлләрнең хәтәр икәнлекләрен төшенәләр. Ир-атларның өсләрендә тун, толып. Тиз генә кайтмаска мөмкин икәнлекләрен болары да яхшы чамалыйлар булса кирәк. Мылтыклы гаскәриләрне күреп алгач, эшнең нindидер кәгазьгә тамга салу белән генә бетмәячәге ачык иде инде аларга. Күбесенең йөзендә күндәмлек, язмышка буйсыну, чарасызлык.

Әхмәтсафа урамга чыкты. Арылган, йончыткан. Таңга

ерак калмый, авыл, шомлы хәбәр көтеп, басылып, чүгеп калган сыман. Сизелеп тора, бүген беркем дә йокламый, авыл уяу иде. Офыкта ниндидер яктылык уйнап алды кебек. «Тагын бер шайтан таңы» дип ачынып уйлап куйды Әхмәтсафа.

Каравыл өе тирәсенә унлап олау җыелган. Олаучыларны ОГПУ вәкиле бер тирәгә җыйнап, нидер сөйли, аңлата иде. Каравыл өенең кечкенә ихатасы алдында киеренке тартыш бара. Кемнәрдер, күрәсең, монда җыелган кешеләрнең туганнары яки бала-чагасы, каравыл йорты эченә үк үтеп кермәкче була, атка менгән ОГПУ гаскәриләре, кулларына камчы тоткан авыл активистлары андыйларга каршы төшеп, капкага якын җибәрмәскә тырышалар. Анда сәер тартыш, шау-шусыз буталыш бара иде...

Тынлык озакка сузылмады. Бер малай үзәк өзгеч тавыш белән:

— Әткәй! Әткәем! — дип кычкырып җибәрде. Тавыш иясенә камчы тоткан бер активист ташланды, һаваны ярып камчы чыжлады.

Баланың иңрәп:

— Күзем... күзем...— дип ачыргалануы ишетелде.

Әхмәтсафа авыр уйлар белән эчкә үтте. Шәмтиев, ике ягында ике гаскәри торган хәлдә, җыелган халыкка соңгы сүзләрен җиткерә иде инде:

— Шулай итеп, туганнар, кәгазьне безнең кулга бирмәделәр, һәркем Минзәләнең үзенә барып, кул куярга буласы булып чыкты. Без канткомда уйлаштык. Авыл халкының эше күп, урык-сурык йөрергә вакыты юк. Аерым-аерым килеп, тамга салганнарын көтеп ятсаң, ай үтәр, дидек. Эшне җиңеләйтергә булдык, бергәләп олауларга төялеп юлга чыгабыз, Минзәләдәге эшләрне бетереп, иртәгә үк, төштән соң кире кайтырга чыгарсыз шул ук олаулар белән. Олаулар әзер. Иптәш Сабиров, кем кайсы атка утыра, аңлатып чык. Кисәтеп куям, кем дә кем урамдагы халыкка коткы таратырга маташып, мин әйткәнне башкача аңлатып азапланса, гаскәриләргә фәрман бирелгән, урында ук атып егабыз. Аңлашылдымы?

Халык бу кадәр кискенлектән телсез калган иде, шулай да «иртәгә төштән соң ук кире кайтып китәсез» дигән сүзләр күбесенең җанында өмет чаткысы уяткан иде, нидер әйтеп, кабат-кабат сорашып-белешеп торасы итмәделәр. Кемдер уфтанып куйды:

— Ходайның язганы булыр инде... Изге ураза айларында...

Сабиров, кулындагы кәгазьгә карап, авылдашларына яны белән баскан хәлдә, калтыравык тавыш белән укый башлады.

— Беренче олау — ат тотучы Сафиулла малае Мөхәммәт. Миргалим мулла, Фазлый мулла, Габдрахман утыралар...

Сабиров укыганда, Габитов, бу эшләргә бөтенләй катнашы юк шикелле, җыелган халык белән рәттән басып, тыңлап торган булды.

Әйтеләсе сүзләр әйтелеп беткән, җыелган халыкны олауларга урнаштыру башланды. Эшнең шома гына баруыннан Шәмтиев канәгать иде, кешеләр чыгып беткәч, каравыл өендәге авыр тынлыкны бозып, күтәренке тавыш белән Габитовка эндәште:

— Кара аны, Габитов, без киткәч, авылда тынычлык булсын. Башың белән җавап бирәсең...

— Бер дә шау-шу чыгарасы килми дә, иптәш Шәмтиев. Кара як бит бу. Халык сарык белән бер. Берсе башласа, икенчесе ияреpгә генә тора...

— Иярмәслек ит! Таң сызылуга, Минзәләгә озатылганнарның хатыннарын каравыл өенә җыегыз, һәркайсына утызкырык камчы. Кайсын базга, кайсын келәткә ябып, телләрен тешләтерлек итегез. Авызларын ачсалар да, сүз әйтерлек хәлләре калмасын. Кемнең кайсы категориягә керүенә карамастан, иң беренче эш итеп, өйләреннән куып чыгарыгыз. Балачагасы белән авылдан сөрегез. Кемнең ике-өч хатыны бар, олы хатыннарын кыйнап ташлагыз, башка хатыннарын авылда байгыш булып йөрүче әтрәк-әләмгә хатынлыкка таратыгыз. Риза булмаганнарны чамалыйсың инде нишләтергә.

— Беләбез, иптәш Шәмтиев. Ризалаштырырбыз, әйе-е...

— Сиңа өч көн вакыт, Габитов, әгәр йөз процент колхоз булмаса, үзеңнең хатыныңны шәрә килеш урам буйлап йөртәбез. Гыйбрәт булсын пешмәгән ячейка секретарьларына.

Габитов, бөрешеп, ияген якасы эченә яшерде.

— Үтәрбез, иптәш Шәмтиев. Бүре көтүе олакса, авылда Сабиров белән миңа каршы сүз әйтүче калмый. Активистларыбыз да бик әйбәт, тыңлаучан кешеләр. Ни әйтсәң, шуны үтиләр. Өч көн эчендә барысы да колхоз булып бетәр, боерган булса...

— Нинди «боерган» ул тагын? — дип җикерде Шәмтиев. — Кем нәрсә боера сиңа, әллә боеручыларың бармы бездән башка?

Габитов кызарып чыкты.

— Тфү-тфү, нәләт, авыздан ычкынды, иптәш Шәмтиев. Йөз процент колхоз булыр, коммунист сүземне бирәм...

— Шулай диген, «боерган»ны күрсәтермен мин сиңа, әнә олаулар китмәгән, сиңа да урын табылыр... Тагын шунысын да исеңдә тот, бүреләр киткәч, этләр батырая. Берсенә дә пащады бирмә, колагыңа киртләп куй.

Габитов эндәшмәде.

Исәнсеф дигән авылга җиткәч, олаудагылар кыбырсып алдылар. «Сәхәр вакыты үтеп бара, кереп чәй генә булса да эчик. Барыбыз да ураза тотабыз, мөселман кешеләр бит сез, нигә ул кадәр имансыз кыланасыз»,— дип ялыну-ялваруларына җавап кыска булды — олауны як-яктан саклап баручы гаскәриләрнең берсе шартлатып һавага атып җибәрде, шуннан соң кабат сүз куертып торучы булмады.

— Шәп килеп чыкты, Дәүләтъяров. Аягың җиңел икән, мондый эшкә гел сине йөртәсе… Әмәкәй тиклем Әмәкәйдән шау-шусыз олавы белән кулакны алып чыгып кит инде. Филипповка әйткәч, ышанмаган булыр әле. Ну булды инде, кузгалып киткәнче, хатын-кыз, бала-чага олауны сырып алгач, күңелгә шик кергән иде, камчы белән яра башлагач, берике мәртәбә һавага атып та җибәргәч, шыр җибәрделәр тагын. Акыра-бакыра, авылны чыкканчы, арттан ияреп бардылар, ну якын килергә курыктылар.— Шәмтиев, көлгән булып, янәшәдә утырган Әхмәтсафаның җилкәсенә суккалап алды.

Әхмәтсафа ни дип әйтергә белмәде. Йөзенә бары хәсрәтле дулкын гына йөгерде. Әлеге хәлләрнең барысын да үз күзе белән күреп, йөрәге аша кичергән иде. Минзәләгә куылучы халыкны нинди язмыш көтә? Кайчан да булса авылга кайтып егылырлармы алар? Гаиләләр кавыша алырмы кабат? Шәмтиев бүлгәләгән категорияләрне игътибар белән кем дә булса яңадан карап чыгармы? Ай-һай, илдә сыйнфый көрәшнең кызган чоры, кат-кат тикшереп торучы табылыр микән… Әхмәтсафа үзе дә шушы көрәшнең уртасында хәзер. Болай җебеп тору килешмәсен дә белә. Ул коммунист, фирка карарларын фәкать тимер мускуллы, нык ихтыярлы көрәшчеләр генә үти алачак. Сафта җебегәннәргә урын юк. Бүгенге хәлләр зур көрәшнең башы гына. Алда әле ниләр күрәсе, кичерәсе булыр…

Олаучылар атларны куаламаска тырышалар, бахбайларны алҗытасылары килми. Саклап баручы гаскәриләр исә һаман ашыктыралар. Олаучылар башы өстендә нагайкалар уйнап ала.

Ык аша чыгып, шактый текә тоелган таудан күтәрелгәч, ниһаять, олауларга туктарга әмер бирелде. ОГПУ вәкиле, олауга төялгән халыкка кузгалмаска кушып, олаучыларны янә үз янына чакырып китерде. Әхмәтсафа да, аягын язасы итеп, шул тирәгә елышты.

Чаналарның берсендә иң ахырдан каравыл өенә китерелгән Сөләйман карт тынгысызлана:

— Имансызлар аркасында сәхәрсез уразага кердем бүген. Кәҗә авылында ни калган безгә? Мөртәт урыслар арасында мәсхәрә итеп утыртканчы, тизрәк Минзәләгә җитик,

Алла коллары. Ник вакыт уздырасыз? Җыен җир бит,— дип каһәрли-каһәрли сүгә иде ул гаскәриләрне.

Әхмәтсафа, картның сүзләрен ишетмәгәнгә сабышып, алга үтте.

ОГПУ вәкиле олаучыларга сәфәрдә бару тәртибен соңгы мәртәбә аңлата иде.

— Монда кадәр әйбәт кенә килеп җиттек. Алда — иң җаваплы өлеш,— диде ул, тавышын баса төшеп.— Минзәлә урманын бертында үтәргә кирәк. Сәбәп-мазар табып туктап тору юк урманга кергәч. Кайсы олаучы туктап кала, шуның маңгаена пуля.

— Атлар өшәнделәр, бик куып булмас... Көне буе ялсыз киләләр бит...— диде Мөхәммәт исемле яшь егет. Олаучыларның күбесе яшьләр, үзләренең нинди хәлдә булуларын аңлап җиткермиләр иде. Олаучы егет, кайнарланып, үзенекен тәкрарлый иде.— Кайтасы да бар бит әле халык төяп. Атларны харап итмәбезме?

— Тилегә сабышма! Сезнең белән гәп куертып торыр вакыт юк. Атларыгыз шәп, үзегез елгыр егетләр күренәсез, аңларсыз кебек, кабат әйтәм, Минзәләгә кадәр туктау юк! Минзәлә урамына кергәч, безнең арттан барасыз, кая барып керергә икәнен үзебез күрсәтербез. Өстәмә бер генә сорау да бирмисез, олаудагыларга монда сөйләшкәннәрне җиткермисез, шушы тәртипне бозучылар, чамалагыз, үзегез дә төрмәдән чыкмыйсыз!

— Төрмә?..— дип кайтарып сорады кемдер.— Без төрмәгә илтәбезме халыкны?..

ОГПУ башлыгы, артыгын ычкындырганын чамалап, боргалана башлады:

— Мин моны болай гына, башыгызга тизрәк барып җитсен өчен генә әйттем. Онытыгыз монда ишеткәннәрне, сүзем бетте, кузгалабыз!

Олаучы егетләр, теләмичә генә, үз чаналарына таба киттеләр. Гаскәри урыныннан кузгалырга ашыкмаган Әхмәтсафага каты гына итеп:

— Сиңа аерым боерык кирәкме, вәкил иптәш? Кузгалабыз, дим бит!

Чыннан да, урманны чыкканчы да, Минзәлә урамында да туктап торулар булмады. Кемнең маңгайга пуля аласы килсен инде? Шәһәргә кереп, киң генә урамнан өскә таба күтәрелгәч, таш койма белән әйләндереп алынган бина янына туктагач кына, олауда утырып килүчеләрнең берсе:

— Бәй, инәңнең баш баласы, Минзәлә төрмәсе бит бу? — дип, аптыраулы-ачыргаланулы сөрән салды.

Аңа йончыган тавыш белән Өммәткол җавап кайтарды:

— Әбиеңә утырмага алып килделәр дип уйладыңмы әл-

лә? Безнең юл шушында өзелә инде, туганнар. Белгәннәрегезне укып керегез...

Олаудагылар бу хәбәрдән өнсез калып, тавыш-тынсыз утырдылар да, исләренә килеп, кисәк урыннарыннан кузгалыша башлаганнар иде, гаскәриләр аларны тиз туктатты:

— Кузгалмаска! Чаналарга ятыгыз! Кем башын күтәрә — атабыз!

Ул арада авыр капкалар ачылып китте, барлык олаулар, чиратлап, шул исәптән Әхмәтсафа утырган ат та, төрмә ишегалдына кереп тулды. Чаналарны гаскәриләр урап алды, кулга алынган Әмәкәй адәмнәрен сафка тезеп, гаскәриләр саклавына калдырдылар, кантком вәкилләрен исә ашыктырып бер бүлмәгә алып керделәр. Әхмәтсафа аруын онытты. Минзәлә төрмәсе дигәнне ишеткәне булса да, бу кадәр котны алырлык, җанны өшетерлек бина дип уйламаган иде. Калын стеналар, авыр ишекләр, өзек-төтек кенә сөйләшү — барысы да иңгә баса, гәүдәне үзеннән-үзе җиргә сеңдерә сыман иде.

Бүлмәдә берничә кеше утыра. Керүчеләргә урын тәкъдим итүче булмады, Шәмтиевтән күрмәкче, Әхмәтсафа да стена буендагы утыргычка сеңде.

— Мин прокурор Госманов булам,— диде түрдә утырган чандыр гәүдәле, усал кыяфәтле кеше.— Йә, кайсыгызда исемлек? — Ул каш астыннан гына әле Шәмтиевкә, әле Әхмәтсафага сөзеп карап алды.

— Монда, иптәш Госманов, үзем алдым исемлекне.

— Бир монда! — Госмановның каты тавышыннан Шәмтиев коелып төште. Калтырана-калтырана кәгазь сузды.

— Барысы да тәртиптәме?

— Тәртип, иптәш Госманов. Шылт иткән тавыш та булмады.

— Анысы өчен ОГПУ җавап бирә. Исемлектә тәртипме, дип сорыйм мин синнән. Категорияләргә кем бүлде?

— Үзем, иптәш Госманов, үзем.— Шәмтиев кисәк төртелеп калды.— Минә иптәш Дәүләтъяров, өлкә комитеты вәкиле белән...

Госманов, беренче мәртәбә күргәндәй, сөзеп Әхмәтсафага карап алды.

— Өлкә вәкиле дә булгач, сорамый булмый. Иптәш, э-э...

— Дәүләтъяров...— диде Әхмәтсафа, кыю рәвештә. Исәбе — сер бирмәү иде.

— Сезнең карашка ничек? Аңлашылып бетмәгән нәрсәләр, сораулар юкмы?

— Сораулар дип... Шулай да исемлектәге бер кешегә шигем калды.

— Кем?

— Сөләйман карт... Нигезле булмады шикелле аны монда китерү.

— Төрмә кунакка гына килеп-китеп йөри торган җир түгел. Ябып тоту урыны бу. Кулга алганчы ныклап уйларга кирәк иде. Хәрби комиссариат вәкиле кайда әле?

Ишек төбендәрәк утырган хәрби киемле, базык, әмма нык гәүдәле яшь кеше урыныннан кузгалды.

— Мин булам, иптәш Госманов.

— Син, иптәш Шәйхетдинов, Әмәкәйнеке бит, әйеме? Исемең Заһир бит, ялгышмасам.

— Әйе,— диде юаш тавыш белән хәрби комиссариат вәкиле.

— Иптәш Дәүләтъяров телгә алган Сөләйман карт кем ул, беләсеңме?

Шәйхетдинов, туры җавап бирәсе итмичә, авыз эченнән ботка пешерә башлады.

— Ни инде, иптәш Госманов, Сөләйман дигән кеше безнең авылда бар инде ул.

— Конкрет!

Шәйхетдинов нигәдер муенын яка астына яшерде. Мондый ук хәлне Габитовта да күзәткән Әхмәтсафа түзмәде, сүзгә кушылды:

— Картны кулга алу өчен нигезле дәлил юк дип саныйм. Габитов белән тәртә башлары эләгешеп киткән димме.

— Кулак түгелме?

— Түгел. Кулак та, мулла да түгел.

— Соң, алайса, ник баш катырасың, кайтарып җибәрегез. Калганнарына ордер тутырабыз. Габитов белән тәртә башы эләккән өчен төрмәгә яба башласагыз, тиздән Әмәкәйдә бер кеше дә калмас.— Күзләрен мөлдерәтеп үзенә карап торган Шәйхетдиновка ачулы караш ташлады.

Әхмәтсафа гаскәри озатуында ишегалдына чыкты. Сафтагылар исәнгерәгән хәлдә әле һаман басып торалар. Әхмәтсафа сак башлыгына юнәлде, хәлне аңлатты. Аның сүзләрен теге гаскәри дә җөпләде.

— Сөләйман абзый,— диде Әхмәтсафа, салкыннан куырылып торган карт янына килеп, артык шауламаска тырышып.— Син кайтып китә аласың, син азат.

Сафтагылар кузгалышып куйдылар.

— Ә без?!

Дистәләгән кешенең шушы тәкатьсез соравыннан Әхмәтсафаның тыны кысылып куйды.

— Сөйләшмәскә! — Мылтык затворы тавышы чыңлап куйды.

Сөләйман карт, Әхмәтсафага игътибар итмәстән, үзенә ияреп чыгып килүче Шәйхетдиновка ташланды. Заһирның үзе

артыннан кузгалганын сизмәгән дә иде Әхмәтсафа. Сөләйман карт килгән шәпкә ике кулын авылдашына сузды:

— Алланың рәхмәте төшсен, Заһирҗанкай, күршекәем. Башка нинди бәлаләр килде микән, дип аптырап торадырыем. Нәмә булды, мин әйтәм, кемгә ярамадым, нәмәгә өтермәнгә китереп тыктылар, дип зар җылап торадырыем. Әле дә син булгансың, Ходайның рәхмәт төшкере. Син әйткәнсеңдер инде, Сөләйман абзый гөнаһсыз бәндә, Алла колы, монда өтермәндә тотмагыз, дигәнсеңдер, әйеме, күршекәем.

Заһир астан гына сафта торган авылдашларына карап алды да, пышылдап кына:

— Бар, Сөләйман абзый, чыгып сыз моннан! — дип, кырт борылып кире прокурор утырган бүлмәгә кереп китте.

Әхмәтсафа урамга чыкканда, Әмәкәйдән килгән олау кире кайтырга кузгалган иде. Мөхәммәт чанасына утырган Сөләйман картның:

— И-и, Заһирҗанның игелекләре-е...— дип сөйләнгәне ишетелеп калды.

Әхмәтсафа арып-талчыгып беткәнен сизде. Ашыкмый гына фатирына кайтырга чыкты. Аны Шәмтиев куып җитте. Йөгергән дә бугай, сулуы капкан.

— Иштең ишәк чумарын,— диде ул, ачу белән.— Бөтен эшне б...ладың, контр! Синең аркада мин закун бозып, бер гөнаһсыз кешене кулга алдыручы булып чыктым әнә. Синнән соң прокурор мине ничек өшкерде, беләсеңме?.. Телеңә тилчә чыккыры, цифрлар үтәлгән иде, «шылт» та юк иде... Контр!

Бу сүзнең бәясен белә иде Әхмәтсафа. Барган җиреннән шып туктап, көчле куллары белән Шәмтиевнең кыска тун якасын эләктереп алды да, аны үзенә үк тартып китереп, теш арасыннан гына ысылдап алды:

— Тагын шушы сүзеңне кабатласаң, бел, үзеңне җибәрәм Сөләйман карт урынына. Контроль цифрың-ниең белән төрмәдә сөрсерсең, аңладыңмы?

Шәмтиев мондый каршылыкны көтмәгән иде, җебеп төште.

— Аңладым, иптәш вәкил, бетте, бетте. Кызып кителгән. Нервылар калмаган инде, суган кыягы сыман бөрешеп беткән нервылар. Шул харап итте, каһәр...

Әхмәтсафа аны тыңлап тормады, борылды да, тулай торакка кайтып баруын онытып, кантком бинасына таба атлады.

* * *

Канткомда кирәкле бер кеше очрамады, әйләнде, тулганды да янә тулай торакка кайтып китәргә булды.

Ике тәүлек диярлек юлда йөрү, авыр тойгылар эчендә

бәргәләнү арыткан иде. Кайткач, тиз генә капкалап, ятып йокларга уйласа да, күзен йокы алмады. Инде кышкы кыска көн үтеп бара, җиргә төн кара канатын җәяргә җыена. Эт булып арган хәлдә йокысыз интегеп ятудан да кыен нәрсә юк. Күз алдында бүгенге вакыйгалар тулгана, колакта туктаусыз чана табаны чыжылдавы. Төрмәгә алып кителгән ирләрнең чарасыз карашлары, Әмәкәйдә хатын-кызларның тавышсыз гына иңрәве, бала-чаганың «әткәй, әткәем» дип ачыргаланып кычкырулары, гаскәриләрнең, авыл активистларының халык өстенә атлар белән килүләре, камчы уйнатулары күз алдыннан китми, юл буе эзәрлекләп килде, хәзер дә туктамаган иде әле.

Әхмәтсафа түзмәде, торып киенде, кәгазь-каләм алды да Рабигага хат язарга утырды. Бу көннәрдә башында җыелган уйларын, күңел түрендә бәргәләнгән хисләрен бер генә кеше — сөекле Рабигасы аңласа аңлар иде. Рабиганың җиңел, сылу гәүдәсе, нурлы йөзе хәтерендә яңарды, битләренә җылы сулышы килеп бәрелгәндәй тоелды, йомшак тавышын ишеткәндәй булып, йөрәге кымырҗып алды. Хыял дулкыны аны күз ачып йомганчы Казан якларына, Рабига янына алып китте. Мәктәптә дәресләр тәмамлангандыр, Рабига да җылы, җыйнак фатирына кайткандыр. Гадәтенчә, тын, бик тын гына моңлы көй көйләп, ашарга хәзерләп алгандыр. Тирән уйлар эчендә ялгызы гына чәй эчкәндер. Хисләнүчән иде Рабига. Ара-тирә сәгатькә күз салып ала торгандыр. Шул арада яктылык бөркелеп торган керфекләре арасыннан яшь тә сыпылып чыгарга өлгергәндер. Ул да сагына торгандыр.

Их, хәзер Әхмәтсафа сөеклесе янында булсын иде! Кош булып очыпмы, җил булып исепме тиз генә барып җит идең аның янына. Әле кайчан гына бергә иде алар! Әхмәтсафа, ТКУдан укудан кайтып, пәлтәсен салып чөйгә элеп куйган уңайга, каршысына килеп баскан Рәбушын (ул аны яратып шулай атап йөртә) ашкынып күкрәгенә кыса. Рабига дәртдәрман тулышкан иренең күкрәгенә башын куеп бертын тора да сак кына ирен читкәрәк этәрә: онытылып китмә, янәсе, дөньяда без икебез генә түгел. Әнә күрше бүлмәдә Шираз дәрес караштырып утыра... Бик мут егет ул, бернәрсәне дә колак яныннан игътибарсыз үткәреп җибәрми. Җитмәсә, Арчадан Җамал апасы кайтып төшкән икән. Ул инде Рабиганы табалап кына тора. Әхмәтсафа белән сүзгә мавыгып китүен күрсә дә, шелтәләп ала:

— Нәрсә, кызый, дөньяңны оныттың? Дәресләреңне кем әзерләр, иртәгә балаларыңа ни сабак бирерсең? — ди төксе генә.

Әйтерсең Рабига чит-ят ир янында шулай бөтерелә дә,

чит бер кеше белән сөйләшеп утыра. Җамалга бусы мөһим түгел. Әхмәтсафа белән сөйләшергә, серләшергә, кайбер чакта бәхәс куертып җибәрергә дә бердәнбер лаеклы кеше дип үзен генә хис итә ул. Рабиганың берәр эшен килештерепөнәп бетермәсә, ярып сала инде:

— Бу кадәр җебек булырсың икән, каян килеп шушы сөлектәй иргә тап булдың син, ә? Адәм имгәге, дисәң, хәтерең калыр, һи-и, мондый ир соң сиңа әрәм бит, әрәм...

Башта бу сүзләрне Рабига күңеленә авыр алып, яшереп күз яшьләрен түксә дә, Әхмәтсафаның Җамалның сүзләренә игътибар итү түгел, апасы Рабиганы битәрләгән саен, үзенең сөеклесен тагын да ныграк яратуын, кирәк булса җанын бирергә дә әзер икәнлеген тоеп, вакытлар үткәч, тынычлана төште. Әхмәтсафа исә мутланып күз генә кыса андый чакларда: «Сөйләнсен, янәсе, тел сөяксез, Җамал ни әйтсә дә, мәхәббәткә күләгә төшерә алмый, киресенчә, мин һаман саен ныграк сиңа тартылам». Җамал чәпчи башласа, Әхмәтсафа кызык тапкан кебек авыз ерып тик утыра, тегесе моны килештерми, отыры котыра гына.

— Утыр инде, шул пешмәгән хатыныңа карап, куанып. Бакчи, син нинди ир инде, шул хатыныңа эш рәте өйрәтә алмагач? Мөкиббән киткән булып утыруыңны әйтерием! Кулына бер кисәк шикәр тоттырган ыштансыз малай-шалаймыни?! Сөенепләр утыра бит Рабиганың минем сүзгә керфеген дә селкетмәвенә. Әллә мин начарга әйтәмме? Ул яшь совет гражданкасы, үрнәк совет гаиләсе төзергә тиешле кеше. Ә ул ни майтара? Күр инде, ике коймагының берсе көйгән. Ризык әрәм иткеч. Җитмәсә, үчекләп, үзең дә көйгән бер коймакны минем алга шудыртасың. Моннан соң ике аягымның берсен атлап кермим фатирыгызга. Шираз булмаса, бүген дә кагылып тормас идем. Арчага машинага утыртып алып кайтырга әзер кешеләр бар иде. Кадеремне генә белеп торасы урынга...

Әхмәтсафа исә көлеп җибәрүдән тыела алмый:

— Мин яратам көйгән коймакны, Җамал. Рабига шундый тәмле пешерә... Мин аңа сокланып туя алмыйм, һәр эшкә дә өлгер синең сеңлең.

Җамал, җенләнеп, коймак тулы савытны Әхмәтсафа алдына җилпеп җибәрә:

— Мә, аша, алай бик яраткач! Күмер ашап, социализм төземәкче буласыңдыр, миңгерәү коммунист!

Рабига нишләргә белми, яшьле күзләрен әле иренә, әле Җамалга төбәп, авызын турсайтып тик тора. Җаныннан да якын күргән Рабига апасына Шираз ярдәмгә ташлана:

— Гел шулай инде син, Җамал апай! Үзең килми тора алмыйсың, килсәң, Рабига апайны җылатмыйча китмисең.

— Тик тор, мин синең сыман шамакай булырга укып йөрмим. Мин кантком кешесе! Кәмит уйнарга болай да остарып беттек инде. Эшләргә генә кеше юк.

Җамал, ачуы килеп, берничә мәртәбә өстәл яныннан кузгалып китмәкче булса да, көне буе Казанда бер оешмадан икенчесенә чабулап йөреп ачыккан. Тамак гүргә кертер, диләр. Хәер, мондый әләгешеп алуга аның да әллә ни исе китми, кайсы оешмага керсә, шунда ачуланышып, кәефе тәмам беткән инде аның бүген, совет бюрократиясенә булган ачуын сеңлесеннән алганын да аңлый. Сеңлесен битәрләп елатты менә. Күзләрендә яшь күренгәнен сизеп алгач, хикмәти Ходa, Җамал тынычланып та калды — күңеле кукәй салды бит. Дәшми генә өстәл өстендә нәрсә бар, рәттән сыпыра башлый.

Җамал «көйгән» коймакларның соңгысын «төпсез казанга» озаткач, Әхмәтсафа, шаян күз кысып, Рабигага дәшеп ала:

— Рәбуш, ник инде коймакларны читкә алып куйдың? Җамалга андый ризык ярамаса да, миңа бик әйбәт бара бит.

Җамал үзеннән көлеп утырган Әхмәтсафага ашардай булып карап ала да кайдандыр бик тирәннән үк чыккан сүзләренең һәр авазын үт суына манчый-манчый:

— Мәгънәсез... Миңгерәү коммунист...— дип, урыныннан сикереп тора, хуҗабикәгә рәхмәт тә әйтми, чаршау артындагы бүлемтеккә кереп, җәелмәгән урын өстенә барып ава. Бу Әхмәтсафа белән Рабига урыны булып, Җамал йокы туйдырмыйча, кузгатып булмаячак аны. Рабига, баш очына пәлтәләрен салып, үзләренә йоклар өчен урын хәстәрли башлый. Барысы да көйләнде, тынычланды, үпкә-сапкаларның эзе дә калмаган, өстәлне җыештырып, иртәгәге көнгә дәресләрен әзерли башлый. Әхмәтсафа исә, өстәл бушавын көтеп, бераз ял итеп алырга була. Рабиганың эше тәмам булгач, сабакка утырачак. Дәресләргә ныклап әзерләнеп йөри ул, төнен китапка багынып үткәрәчәк, таң беленми йокларга ятмаячак...

Хыялда гына булса да сөеклесе янына кайтып килү, Җамалны, Ширазны искә төшереп алу тынычландыра төште Әхмәтсафаны. Ул сүрәнләнеп барган утка карап алды. Әле кәгазьгә бер генә сүз дә төшмәгән икән бит. Бергә чактагы кадерле минутларны искә алып, бөтенләй онытылып киткән. Тик истәлекләр генә һаман күңел түреннән югалмыйлар, аның ихтыярын богаулап торалар.

Уе Җамал тирәсендә бөтерелеп алды. Бу чибәр, яшь хатынны күптәннән белә. Әхмәтсафа Хивада чакта, Җамал мәркәз юлламасы белән округ комитеты эше белән танышырга

килеп чыккан иде. Җиңел арбага рәттән утырып, шәһәр буйлап көне буе йөргәннәр иде. Рабиганың бертуган апасы икәне башына да килмәде ул чакта.

Әхмәтсафа Хивадан Каргалыга кайтып кергән көнне аны өйләрендә иң беренче кеше булып Җамал каршы алыр дип тә уйламаган иде.

Ул кайтып кергәндә, өйдә беркем дә юк, түр яктагы тәрәзә янында бер яшь хатын-кыз ниндидер кәгазьләр белән әвәрә килеп утыра иде. Әхмәтсафаның җилкенүле:

— Исәннәрмесез-саулармысез,— дигән тавышына теге хатын битараф кына башын күтәргән иде, авызын ачты да калды.

Әхмәтсафа да бер караш ташлауга таныды аны:

— Җамал? Сез...

Хатын урыныннан сикереп торды.

— Әйе, мин... Сине кайда күргән идем соң әле... Тел очымда гына тора, әйтә алмыйм. Хәтер дисәң, хәтерең калыр...

— Хивага килгән идегез бит. Тәҗрибә таратып йөрдегез. Мин сезне окружком кушуы буенча озатып йөрдем. Ул көнне минем карамакта булдыгыз,— дип, егет көлеп җибәрде. Хатынның үзенә сырпаланулары исенә төшеп, битенә алсулык та тибеп чыкты. Моны хатын да сизеп, карашын читкә алган булды.— Инструктор идем окружкомда, Әхмәтсафа Дәүләтъяров булам.

— Әхмәтсафа Дәүләтъяров... Син буласыңмы инде минем сеңелемнең башын әйләндергән егет...— Җамалның тавышы кырысланган шикелле тоелды.— Исемә төште, әйе, йөрдек. Ну, син исеңдә тот, окружком кушмаса, мин сине яныма ике адым якын җибәрмәс идем. Малай-шалайдан туйган. Ә болай бик күңелле йөрдек без синең белән. Ярый әле сиңа күзем төшмәгән, күңелгә ятышлы егетләрне тиз генә кулдан ычкындырмыйм мин.— Инде хәзер Җамал сәер генә көлеп куйды.— Баксаң, кияү тиешле булып чыктың.— Җамалның күзләре янә серле ялтырап китте. Бу караште ниндидер тыелгысыз дәрт, хәтта ниндидер әрсезлек бар иде кебек.— Шулай, сеңелкәш тырнаклырак булып чыкты диген.— Җамал, җавап көтмәстән, нык басып Әхмәтсафа каршысына килеп басты, күрешергә кулын сузды.

Әхмәтсафа йортта үзен хуҗаларча тоткан бу хатын-кыз затына уңайсызланып кына ике кулын сузды. Һаман аптыраулы халәттә басып торуын абайлап, сорау биргән булды:

— Безнекеләр кайда соң?

— Һе, кайда булсын, халык эштә. Синең кайтуны көтеп утырсаң. Белүемчә, май ахырларында ук кайтырга тиеш идең бит син. Рабига төн йокысыз калды инде. Сине көтеп көтек булды.

— Барып чыкмады.

— Әйбәт булды кайтуың, Рабига саргаеп үлә инде дип, куркып йөридер идем. Җитмәсә, артыннан бер өер җегет йөри. Берсенә дә күз салмады, күрәсең, каты сөйләшеп киткәнсез инде. Хәер, безнең нәсел нык холыклы. Сүз бирсә, өзми калмый.

— Без вәгъдәләшкән идек.

— Буржуй сүзне сөйләп торма инде, нинди вәгъдә ул? Тагын, ярәшкән идек, дип тә җибәр. Беләсең килсә, коммунистлар социализм төзү эшенә генә ант бирә алалар. Калганы барысы да сафсата! Ант, вәгъдә дигәннәрне китап та яратып бетерми аны. Рабиганы әйтәм, кайбер җегетләрен ошаткан идем. Соңгысы бигрәк тә үҗәт кыланды. Муса Җәлилов дигәнен әйтәм. «Әхмәтсафа кайтмадымы әле?» — дип керә дә җитә. Үзе сине сораган була, үзенең күзе Рабигада. Бәхетең, нык холыклы кызга күз салгансың. Тәки сынып төшмәде. Җегете шәп иде болай, үткен иде...

Әхмәтсафа каршысында торган Җамалны урап үтте дә мич янындагы утыргычка барып утырды. Арылган, йончылган, шулай да Җамалның сүзләре күңел түрендә давыл куптарды.

— Муса Җәлил? Безнең авылда нишләп йөри ул? Әллә Каргалыда эшлиме?

— Юк ла инде, губкомда эшли иде, Рабига комсомол ячейкасын иярли бит. Серләре күп булгандыр. Тынычлан, китеп барды инде ул.

— Муса хәзер кая китте соң? Монда йөри дигән идегез...

— Сезләп-безләп тормале, ачу китереп. Муса Мәскәүгә китте, укырга. Университет дип хыяллана. Әле үзем дә уйлап торам, әллә Мәскәү ягына китәсе...— Дөресен әйткәндә, Муса җилкенүле Җамалның күңелен яулап өлгергән булса кирәк. Яшь аермасы булмаса...

— Мин дә укырга чакыру алдым, Казаннан...

Җамалның күзләрендә очкын кабынды.

— Казан? Вәт, мин дә Казанга китәм, алайсам...

— Сез... әй, син лә, Кокандта эшләмисеңме инде?

— Юк,— дип кырт кисте Җамал.— Күрәсем дә килми үзләрен. Бер үзбәккә, зур партия работнигына кияүгә чыккан идем. Яңа совет гаиләсе төзим дип, тормыш зинданында зар чиккән меңләгән үзбәк хатын-кызларына үрнәк булырлык яшим дип ашкынып чыктым кияүгә. Өйләнешкән көнне үк минем үзбәгем битемә пәрәнҗә бөркәп, кышлакка, әткәсе-әнкәсе янына кайтарып ташламакчы була бит, әй... Кәҗә бәрәнемени? Кияүгә чыккач кына белдем, мин аның өченче хатыны икән. Өйләнә дә, кышлакка кайтарып ташлый бичә-

сен. Кокандта исә буйдак булып йөри. Шәп бит. Менә син йөр Үзбәкстан буйлап, үзбәк хатын-кызларының бәйсезлеген тәэмин итәм дип. Билгеле, кышлакка бару түгел, шәһәрдә калуны да күз алдыма китерә алмадым. Алдашуны җенем сөйми, тавыш чыгардым. Ризалата алмагач, миңа кизәнеп маташа иде, күлмәк астына яшергән револьверымны тартып чыгардым да «шарт», мин сиңа әйтим.

— Үлдеме? — дип сорау биреп ташлады Әхмәтсафа.

— Үлә ди, нәләт төшкән нәмәрсә. Мин аңа төзәп атканмыни? Шыр җибәрде үзбәгем. Идәнгә ятып шуыша. «Бетте, мин андый начар имәсмен, ялгыш кына сүз кузгаттым,— дигән була.— Зинһар, өлкә комитетындагы иптәшләргә тишмә бу хакта»,— дип ялвара.

— Ничек бетте соң бу эш?

— Ничек булсын, шул ук көнне партиядән чыгарып аттылар үзен. Миңа эләксә... Әйтәм бит, безнең холык шундый, өзми туктау юк. Аннан күрәм, болар миңа каныга башладылар, документларны алдым да кайттым да киттем. Нишләп чиләнеп ятарга тиеш әле мин анда. Үзләре йөрсеннәр хатыннарыннан пәрәнҗә салдырып. Мин гарык инде.

Ишек ачылып китте. Акка кара бөрчек сибелгән күлмәк кигән Рабига килеп керде. Рабиганы күргән уңайга, Әхмәтсафа, урыныннан сикереп торып, каршысына ташланды.

— Рабига! — Тамагына төер утырып, сүзсез калды.

Рабиганың куркудан йөзенә алсу тимгелләр бәреп чыкты. Уңайсызлануыннан, үзе дә белештермичә, ишекне ачты да өйалдына сикерде, үзе, ачмасыннар дигән сыман, арты белән ишеккә сөялде. Әхмәтсафа, сак кына этәреп, ишекне ачты һәм караңгы өйалдында Рабиганың кулларын эзләп тапты.

— Рабига...— диде ул янә, сулышы кабып.

— Кайттыңмы, бөтенләйгәме? — диде кыз, хәлсез тавыш белән.— Быел да кайтмый калырсың дип уйлаган идем инде. Соңаргач...

— Бөтенләйгә...— диде Әхмәтсафа. Кыюлана төшеп Рабиганы кочагына алмакчы иде, ишек ачылып китте, аларга, күзләрен шар ачып, Җамал карап тора иде.

— Берәүнең җегете кайткан,— диде ул, сеңлесенә мыскыллы караш ташлап. Әмма бу тавышта көнләшү чаткылары күбрәк иде бугай.— Егет күргәч, һушын җуйды, кер өйгә, нәрсә анда торасың торараштай!

Рабига да исенә килде, кыенсынып кына өйгә үтте.

— Минем апам, Җамал исемле.— Рабига, озын керфекләрен сирпеп, апасына карап алды. Аннан куркамы, әллә шулай егете белән рәттән басып торуыннан каушый-ояла идеме, йөзеннән һаман кызыллык китми, аяк буыннары җиңелчә генә калтырый да иде бугай әле.

— Һе, таныштырды. Без, үскәнем, Дәүләтъяров белән Хива урамнарын буйлап, шәп атларда рәттән утырып, парлашып үткән кешеләр инде. Күптәнге танышлар, фиркадәш дуслар. Шулай бит, иптәш Дәүләтъяров?

— Әйе шул, Хивага килгән иде Җамал. Миңа аны көне буе төрле оешма-учреждениеләргә озатып йөрергә туры килде.

Рабига йөгереп диярлек өстәлдәге самоварга барып тотынды.

— Син юлдан гына бит әле, Әхмәтсафа, чәй куеп җибәрим.

— Көйлә инде җегетеңне, серләрегез дә бардыр.— Җамал, ниндидер риза булмаган кыяфәт белән, ишегалдына чыгып китте.

— Һай-ли, бу апаң синең, Рабига. Усал күренә.

— Сөйләшүе генә шулай аның, Әхмәтсафа. Ә болай бик йомшак күңелле, туган җанлы кеше үзе. Аннан эше шундый булды бит — гел көрәш, тартыш. Шуңа кырысланган. Без аны яратабыз, мәрхәмәтле ул. Чыгырдан чыгып, төртмә сүзләр әйткәләсә дә, үткәреп җибәрәбез инде...

...Әхмәтсафа Казанга Җамал белән килеп төште.

Җамал укуга барам дип ашкынып килсә дә, кулында ни юллама, ни чакыру булмагач, җитмәсә, соңарып та килделәр, аны ТКУга алмадылар, башка уку йортына керергә теләмәде ул, өлкә комитеты аша Арча кантоны Чүриле волостена хатын-кыз эшләрен оештыручы булып китте. Күп тә үтмәде, Арчаның үзенә үк күчерделәр. Әмма белем җитмәү нык сиздерә иде, менә гыйнвар башыннан ул ТКУ курсларында укый башлады. Кызык хатын Җамал, җилле кеше.

...Рабиганы исә Казанга икенче елны гына алып килә алды ул.

* * *

Җилкенүле, күңелле көннәр иде. Бөтен шәһәр кайный — шушы көннәрдә Казанга бөек пролетар язучысы Максим Горький килә! Моны иң беренче мәртәбә Әхмәтсафа Шамил Усманов авызыннан ишетте.

1928 елның августы иде ул. Каникул чорын Каргалыда үткәргән Әхмәтсафа Казанга Рабига, Шираз, Бибкәй белән бергәләп килеп төште.

Алып килде дигәч тә, тиз генә һәм җиңел булмады ул. Рабиганың әнисе Хәлимә апай кызының кайдадыр белем эстәп йөргән бер егет — Әхмәтсафага ышанып йөреп, «утырып» калуыннан шикләнеп-шөбһәләнеп тә йөри иде бугай инде. Ара-тирә, өйдә үзләре генә ялгыз калган чакларда, Хәлимә апай:

— Син, кызый, һавадагы торнага ышанып, кулыңдагы чыпчыкны ычкындыра күрмә. Башлы-күзле булу күлмәк алыштырып кию генә түгел. Казан якларыннан безгә әүвәл бер сәүдәгәр килеп чыккалый иде. Ул: «Укыган кеше — чукынган кеше»,— дия торганые. Әүвәл чукынмаган кешеләрне зур мәптәкләргә алмаганнар, имеш. Сабакка йөри башлаганчы, мөселман булса да, укуы беткәнче, муенына тавык тәпие асканнар. Уйлап-уйлап йөрим дә, ул синең җаныңны кымтырыклап торган егет яңадан да яныңа кайтыр микән? Бер дә ышанасы килми.

— Ә мин Әхмәтсафага ышанам!..

— Ирләргә ышанма, Иделгә таянма, дигән әүвәлгеләр.

— Борынгылар сүзе ярап бетми бит ул хәзер, әнкәй.

— И акылсыз кыз, җүләр баш. Беркайчан да үзгәрми торган ике генә нәрсә бар — берсе аның Коръән аятьләре, икенчесе — борынгылардан калган хикмәтле сүзләр,— диде Хәлимә апай, ачулана төшеп.— Инде Җамал апаңа акыл кертеп булмас, үз акылы үзендә, үсмер чакта ук тәртә арасыннан чыгып китте. Син бит бөтенләй икенче табигатьле, кызым. Йомшак син, сабыр. Сабырлык — иң күркәм сыйфат бәндә өчен. Сабырсыз кыланган кешедән дә яман кеше юк. Күр, шушы Каргалыда гына күпме егетләр сиңа сүз кушарга тилмереп йөри. Су сөлегедәй үзләре, Сал-Сал батыр кебек җегәрлеләр, кулларында ут уйнаталар. Син китаптан башканы белмәгән егеткә чат ябыштың, ачуым да бер килмәгәе...

...Әлеге «әңгәмә» хакында, җәйге ялга кайткач, Рабига көлә-көлә Әхмәтсафага үзе сөйләгән иде, егет хафага калды. Чыннан да, уйларга кирәк. Яше егерме икедә. Рабига аннан бер яшькә кече. Авылда бу яшьтәге кызның кияүгә чыкмый йөрүе гайре табигый хәл дип санала. Андый кызлар хакында: «Сазаган, кияүгә чыкмыйча утырып калган кыз»,— дип көлеп җырлар да чыгаралар. Зәһәр җыр, мыскыллы җыр:

Яшел тасма телеп тактым
Кәҗә мөгезләренә.
Егермедән үткән кызлар
Нәсел үгезләренә.

Йорт хуҗасы юаш булса, мондый җырны тәүфыйксыз егетләр өй турыннан бер төн эчендә өчәр мәртәбә «яңгыратып» үтәләр. Чыдасаң чыда, чыдамасаң юк. Аптырашта калды Әхмәтсафа, һаман-һаман сузып йөрсә, ике арага суык җилләр үтеп кермәсме? Әнә Рабига да, авыр сулап:

— Казанда кызлар бетәсе түгел, безнең ише авыл кызларына исең дә китми торгандыр инде,— дип тә ычкындырды.

Шул ук вакытта «илдә чыпчык үлми» дип, сөйгән ярыңны җитәкләп калага алып китеп, йортсыз-нисез хәлдә аны җәфа чиктереп йөрүе дә эш түгел. Чыпчык үлми дә, рәхәт тә күрми шул. Эшләрнең көйләнеп беткәнен көтеп утырсаң да әйбәт түгел. Йөргән аякка җон иярә, ди, йөрсәң-эзләсәң, торырга фатиры, Рабигага эше дә табылыр иде. Тәвәккәлләргә кирәк! Ашыктырмый чара юк, хәлләр бөтенләй икенче төс алуы бар. Рабигалар бер кичне клуб итеп үзгәртелгән мәчеттә театр куйдылар. Кәрим Тинчуринның «Сүнгән йолдызлар»ы иде сәхнәдә. Әхмәтсафа Рабиганың җаны-тәне белән бирелеп уйнавына сокланып утырды. Ә быел гына җиденче сыйныфны тәмамлаган Ширазның сәхнәдәге уенын күреп исе китте. Коеп куйган артист, бүгеннән театр училищесына илт тә бир!

Әхмәтсафа вакыты булганда Казан театрларына йөргәли иде, күп артистларны күреп белә, хәтта якташы, Орск якларында туып-үскән Хәким Сәлимҗан дигән җор телле артист белән сөйләшеп тә торганы бар. Казан сәхнәсендәге артистлардан ким уйнамый Шираз. Әхмәтсафа, күңеле булып, эченнән генә «шайтан малай» дип куйды. Хәким Сәлимҗанның җитди рәвештә әйткән сүзләре дә хәтердә яңарды:

— Җанлана татар театры. Матур-матур әсәрләр языла. Әмма театрга яшь көчләр кирәк, карт артистлар, иске багаж белән генә татар театрын үстереп булмаячак, — дигән иде ул бер очрашканда.

Менә Шираз коеп куйган артист булачак. Тамчы да шикләнми моңа! Казанга алып китәргә кирәк үзен, зур артистларга күрсәтеп карарга тиеш ул аны.

Су чокырга җыела дигәндәй, Бибкәй дә җиде сыйныф тәмам итеп, Шәмсия әнкәсе белән Каргалыга кунакка кайтып төште. Кызга акыл керә башлаган, авылдан китәсе, туганнарыннан аерыласы килми борлыгып йөри. Шуларның барысы җыелып, ахырда Әхмәтсафаның җаны тулышты, ул беркөнне Рабига янына мәктәпкә китте. Яңа уку елына хәзерлекнең кызган көннәре, кыз көннәрен мәктәптә үткәрә иде. Барып керде, Рабиганы эзләп тапты һәм, кызның аптыраулы карашына игътибар итмәстән, кеше-фәлән ишетер дип тә уйлап тормады, икеләнер урын калдырмыйча ярып салды:

— Җыен, Рәбуш, китәбез! Шираз белән Бибкәйне дә үзебез белән алабыз.

...Хәлимә апай бу хәбәргә сөенсә дә, артык җебеп тә төшмәде.

— Болай гына җибәрмим Рабиганы! — диде ул, тавышын күтәрә төшеп. Бу җыйнак гәүдәле карчык беркайчан да төшенкелеккә бирелми, шаян-тапкыр сүзле. Шираз суй-

ган да каплаган, гел әнисе инде. Әмма җитди эш булса, шаянлык, шуклыклар онытыла, Хәлимә апай җитдидән дә җитдигә әйләнеп куя, әйткән сүзеннән чигенер димә.

— Әнкә-әй...— дип суздыРабига.— Сөйләштек бит инде...

— Юк, җибәрмим болай гына! — диде Хәлимә апай, каты итеп һәм, миннән башка сүз көтмәгез дигәндәй, иреннәрен нык кысып, мич алдында нидер эшләп азаплана башлады.

— Әби...— дип, җайлап кына сүз башламакчы иде Әхмәтсафа, Хәлимә апай җәһәт егеткә күтәрелеп карады. Аның күзеннән очкыннар чәчелде. Апай зәһәрләнеп карадымы, әллә шаяртасы итәме?..

— Әле «әби» түгел шул... Менә никах укытсагыз, китап кушканча кавышсагыз, «әби» булырмын. Аннан соң теләсә нишләгез.

«Дин — халыкка әфьюн ул. Аннан башка да шәп яшәргә була» дигән фикергә ияләнә башлаган Әхмәтсафа, аптырап, муенын кашып алды.

— Никах дип...

Рабига да үз сүзен әйтәсе итте:

— Әнкәй-й, без бит өйләнешмибез. Язылышу турында сүз бармый. Казанга китү, Ширазны, Бибкәйне укырга урнаштыру турында сөйләшәбез.

— Бара шул! — дип, кызын шелтәләп алды Хәлимә абыстай.— Син нәрсә, яхшыдан яман туган нәмәкәй сыман... Егет кешегә болай гына ияреп китәргә... Китәсең икән, никахлашып, ир белән хатын булып китәсез. Вакыты җиткәч, язылышырсыз. Анысы качмас, Ходай каршысында дөрес булыгыз сез.

Бу сөйләшүнең шаһиты булган Бибкәй, чытлыкланып, Рабигага килеп сарылды.

— Ур-ра, Рабига апа минеке булачак! — диде ул, өйне яңгыратып.— Дөньяда иң матур апам дип йөртермен сине! — дип, битеннән үбеп тә алды.

Рабига, кыенсынып, Бибкәйнең чәчләреннән сыйпап алган булды.

— Шушы әнкәй...— диде, авызын турсайтып.— Кеше ишетсә...

— Бәрәмәч, ишетсә ни-нәрсә булган? Чыгасың килмәсә, әйт, Әхмәтсафага чыкмыйм, диген. Әнә егетең дә бәлшәеп утыра. Алам дип тормый әле бер дә. Андый сүз ялгыш та колакка кермәде. «Әби» дию генә әле ул...

Әхмәтсафа чәчрәп урыныннан торды:

— Ни сөйлисең, Хәлимә апай! Ничек инде...— Ул нәүмизләнеп Рабигага карады.— Без бит совет яшьләре, никах дисәң, көләрләр бездән...

Рабига да аны хуплады:

— Никах дип, әнкәй... Хәзер бит инде башка замана.

— Кара син боларны!..— дип бот чабып куйды Хәлимә апай, тәмам аптырап.— Акыллы эштән беркем дә көлми, җүләр эштән көләләр. Никахсыз тормыш кормакчы булалар бит, адәм страмнары. Тотыгыз капчыгыгызны, ачуым бер килмәгәе, хәзер чыгарып җибәрәм ди мин кызымны бер егет кисәгенә ияртеп. Алайса, аяк та атламыйсың, Рабига! Өйдән чыгып китәсең юк! Фатихамны көтмә дә! Китәбез Оренбурга, фатиры да, ачтан үлмәслек эше дә табылыр. Гел кеше күзенә карап яшәү булмас!

Рабига, елап, мич арасына кереп китте.

Нишләргә дә белми Әхмәтсафа, идән уртасында башын иеп тик басып тора.

Хәлимә апай үзе ярдәмгә килде.

— Әгәренки, иманыгыз зәгыйфьләнеп, куркып йөрисез икән шәригать белән ата-баба йоласыннан, никахны Оренбурга барып укытыйк соң?.. Кем икәнегезне дә белмәсләр. Бер бик гыйлемле хәзрәт бар, бүген үк белешеп кайтам, иртәгә, боерган булса, никах укытырбыз.

Шушы йодрык кадәр генә карчыкны икәүләшеп җиңә алмаячагын аңлаган яшьләр риза булдылар. Никах укыткач, җаннарында үзләре дә аңлата алмый торган бер җиңеллек хасил булды. Югыйсә тормыш арбасына җигелергә җыеналар, нинди җиңеллек хакында уй килсен башка. Юк икән шул, өлкәннәрнең фатихасы һәр эштә кирәк икән.

Оренбурда Әхмәтсафа Гомәр агасы янына кереп, аны яшь бичәсе — Рабигасы белән таныштырып чыкты. Гомәр агай инде шактый бирешкән, борынгы бер карт сыман иде.

— Китәбез инде, китәбез,— диде ул уфтанып, Әхмәтсафаның кулына сак кына кагылып.— Дөнья сезгә кала, балакайлар. Оренбур мәркәз иде, татар мәркәзе иде. Хәзер юк инде, без ашкынган идеаллар сүнеп бара, ислам нуры азларның гына җанын яктырта. Денсез кавем басып бара илне. Бик куркам, Әхмәтсафа энем, денсез илнең киләчәге юк бит аның. Ходайдан узып эш майтармакчы булалар да, белмим шул, барып чыгар микән... Ленин кәгазьдә сурәтләп биргән хыялдагы яшәеш агачы белән табигый үсештә булган тормыш агачы арасында аерма зур, ай-һай, зур шул.— Яткан түшәгеннән калкына төште.— Җәмәгатең ни атлы соң әле? Хәтердән дә чыкты инде...

— Рабига...— диде кыз, керфекләрен түбән төшереп. Ул бу өйдәге затлылыкка, китапларның күплегенә исе китеп тора иде.

— Күркәм исем... яз... Мәгънәсе — яз дигән сүзне белдерә,— дип, нигәдер урысчалап та өстәп куйды.— Весна!

Үзең дә яз шикелле якты, матур син, сеңлем... Матурлыкның кадерен бел, энем.— Ул инде Әхмәтсафага карап сөйли иде.— Матурлык үз бәясен алырга хаклы. Иң гүзәл нәрсә — иҗтиһад итү. Аягөсте йоклап йөрүче беркайчан да матур була алмый. Анда булган матурлык та йоклый. Баеп баручы кояш бик матур, әмма ул тиз уңа, бетә, караңгылык эченә кереп югала. Сез югалмагыз, балакайлар... Кешеләр белән сөйләшә белмәүче — телсез; табигатьне аңлый алудан мәхрүм җан — чукрак; игелекле гамәл мәгънәсенә төшенмәгән — уйсыз. Андыйлардан ерак йөрегез. Бәхетле булыгыз!..

Әхмәтсафаның күзләренә яшь тыгылды. Ул ашыгып хушлаша башлады.

— Рәхмәт, агабзыкай. Изге сүзләрең, фатихаң өчен рәхмәт. Без кузгалабыз инде, тизрәк терелә күр, сиңа һич килешми болай яту.

Гомәр абзыйның йөзе яктырып китте.

— Әле бирешергә исәп юк иде,— диде ул, авыр тын алып.— Салкын тигездем бит уйламаганда. Ә сез ашыкмагыз әле. Хәзер кай якларга юл тотмакчы буласыз?

— Казанга. Белем алырга исәп, үзебезчә...

— Ә-ә, Казанга укмыни?! Татарның мәркәзе инде ул. Оренбур биреште. Кибеп бара. Кызганыч... Укымышлы кешеләр булып кайтырсыз инде. Кайтсагыз... Казан булдыклыларны җибәрергә атлыгып тормый ул. Башта җегәрне сыгып ала, аннан гына җибәрә. Зыялылар буласыз, димәк, киләчәктә. Аһ, бар иде заманалар...— Гомәр абзый күзләрен тәрәзәгә төбәп тын калды. Янә авыр сулап куйды. Сүзен дәвам итте.— Мәгърифәтчеләр, диләр иде безләрне. Җәмгыятьтә акылның өскә чыгуына ышанучы беркатлы җаннар. Менә кемнәр алар зыялылар. Укымышлы булу — әле зыялы булу дигән сүз түгел. Зыялыларны түрәләр, хакимнәр яратып бетерми. Аларга үз фикереңне генә әйт, шуны расларга омтыл — хәзер гаугачы, җәнҗалчы исеме тагып куялар. Баштан кичте инде.

— Дөньялар үзгәрде бит инде, агабзыкай. Укымышлы кешегә караш үзгәрде.

— Зыялыга караш беркайчан да үзгәрми ул, энем. Яман аның хәле, яман. Халыкка якын булсалар, үз хәлләре мөшкелләнә,— ачлык, хәерчелектән качып котыла алмыйлар, хакимнәр аларны үзләренә якын китерми тек китерми инде. Алар исем өчен бер-ике кешене үз даирәсендә йөртә. Башкаларны бар дип тә белми. Кирәкми аларга милләт мәнфәгатен кайгыртучылар. Электән шулай килде инде ул. Хәзер генә үзгәрер микән? Кем гаепле? Зыялы дип аталган кавем бик чуар. Бәхәс, тарткалаш, ызгыш алар арасында. Килешеп эшләргә сәләтсез кавем.

Әхмәтсафа, күңелсезләнеп калган Гомәр абзыйның күңелен күтәрәсе килеп:

— Бу хәлне төзәтәбез аны, без бит яңа чор кешеләре, зыялыларыбыз, һичшиксез, элекке мескен хәлдә яшәмәс,— дип әйтеп ташлады.

Гомәр абзый көлемсерәп җавап кайтарды:

— Сак бул, энекәш, күп нәрсә төзәткәндә ватыла. Яңадан төзәтеп булмаслык итеп...— Барысы да көлеп җибәрделәр. Әмма бу көлү күтәренке көлү түгел иде.

...Казан вокзалы. Поездлан төшеп, ыгы-зыгы килгән арада, Әхмәтсафа як-ягына каранып алган иде, каршысына килүче Хәким Сәлимҗан белән Шәриф Камалны күреп, кулындагы авыр чемоданын җиргә дык итеп кенә куйды да аларга каршы китте. Билгеле, аларның егеттә бер эшләре дә юк, әмма Әхмәтсафаның аларда эше бар. Ул, үзенә игътибар иттерәсе килеп, ашыгып үтеп баручы Хәким Сәлимҗанның юлына төште, тегеләр исләренә килгәнче, шаяртып сүз башлады:

— Заданиегезне үтәп килеш, иптәш Сәлимҗан!

— Нинди задание? Каян киләсең? — дип аптырап туктап калды таныш артист.

— Каргалыдан киләм. Оренбурдан. Менә бер егетнең бик тә артист буласы килә.— Ул чемоданнар белән мәшәләнгән Ширазга ымлады.

Хәким Сәлимҗан, күрер күзгә юаш кына, җитмәсә, юлдан шактый йончыган, таушалган үсмергә карап, күтәрелепбәрелмичә генә сорау биреп ташлады.

— Сәхнәне күргәнең бармы соң? Зиһен яклары ничек?

— Авылда катнашмаган кичәсе юк. Спектакльләрдә дә катнаша. Әле «Сүнгән йолдызлар»ны куйдылар. Артист инде, ясап куйган кебек.

— Табигый булсын ул, ясап куйган сыман булгач...— Сүзгә моңарчы бер читтәрәк торган Шәриф Камал да кушылды.

Әхмәтсафа, үзе дә сизмәстән:

— Исәнлек-саулыкмы, Шәриф абзый,— дип, күрешергә кулларын сузды.

Шәриф Камал, күзләрен кыса төшеп:

— Төсмерләгән дә кебек... Оренбурда күрештекме соң? — диде, акрын тавыш белән. Егетне таный алмаганга кыенсына иде шикелле ул.

— Әйе!..— Аларны тоткарлавына үз-үзен битәрләгәндәй, ашыгып, Шәриф Камал сүзен җөпләде Әхмәтсафа.— Оренбурда сез балалар йортында директор идегез. Без барып кичәләр оештыра идек. Аннары ТИНОда әдәбият түгәрәге оештырдыгыз...

Шәриф Камалның йөзе яктырып китте.

— Тукта, тукта. Исемә төште! Ут борчасы шикелле тиктормас егет — Әхмәтсафа Дәүләтъяров буласың! Шәп егет! — дип, Хәким Сәлимҗанга борылды.— Кызык чаклар иде.— Өстәп куйды.— Авыр иде, кызык иде. Яңа тормыш төзибез дип җенләнгән чак. Ченәкәй, Афзал Таһир, Муса Җәлил... Һай, санап бетермәле түгел... Истән чыкмый берсе дә...— Хәким Сәлимҗанга сер итеп кенә әйткәндәй дәвам итте.— Оренбур ераклаша бездән, ераклаша, туган. Ул елларның тарихын бөртекләп җыясы иде. Бу эш сезгә, яшьләргә, кала инде.

— Менә сиңа тагын бер задание! — диде Хәким Сәлимҗан.

Көлешеп алдылар.

Хәким Сәлимҗан Ширазга сынаулы караш ташлады да кулын аның җилкәсенә салды.

— Ничек, егет, артист буласың киләме?

— Килә шул, абый.

Ширазның ачык итеп, чатнатып җавап бирүе ошап китте бугай, телен шартлатып:

— Хуп, егет, бик хуп,— диде.— Нindirәк спектакльләрдә катнашканың бар?

Шираз санап китте:

— «Галиябану», «Асылъяр», «Сүнгән йолдызлар»...

— Кара син аны, авыл сәхнәсе генә димәссең! «Сүнгән йолдызлар»да кемне уйнадың?

— Мәхдүм ролен...

Хәким Сәлимҗан яктырып китте. Эшне хәл ителгәнгә санап, Әхмәтсафага борылды:

— Иртәгә үк Гомәр Дәүш янына барыгыз, вакыт тапсам, мин дә кагылырмын, бер-ике кәлимә сүз әйтермен егет файдасына. Гомәр Дәүшне беләсеңме?

Бу сорауга Әхмәтсафа мәзәксенгән шикелле каударланып җавап кайтарды:

— Белмичә! Дәүләт театрының баш режиссеры ич.

— Шәп, яратам зирәк егетләрне! — Хәким Сәлимҗан көлә-көлә китәргә кузгала башлаган иде, Шәриф Камал, нидер исенә төшеп, аны җиңеннән сак кына тартып туктатты һәм Әхмәтсафага эндәште:

— Кара әле, туган, Оренбурда гыйлем иясе бер карт яши иде. Гомәр Дәүләтъяров. Сезнең нәселдән түгелме ул? Исәнме икән әле ул?

Мондый сүзләрне кемнән генә ишетмәде инде Әхмәтсафа. Болай читтән караганда тыныч, тыйнак холыклы, шаушуларны җене сөймәгән, «мин» дип күкрәк сугып йөрмәгән Гомәр аганы белмәгән татар зыялысы юк. Ул көр тавыш белән җавап кайтарды:

— Безнең агабыз була ул. Казанга китәр алдыннан күрешеп, хәл-әхвәлләрен белешеп чыктык менә...

— Рәхмәт,— диде Шәриф Камал, бер үк вакытта сабырлыгын югалтмыйча һәм куанычын да яшермичә.— Андый олпат затлар сирәк ул безнең халыкта. Халкыбыз күңеленең бар асыл сыйфатын үз җанына сыйдырган ил агасы бит ул. Халык андыйларга һәрвакыт мохтаҗ. Кызганычка каршы, мөхтәрәм затларыбызның кадере юк шул. Хәер, зыялыларыбыз сөттән ак, судан пакь түгел. Олпатлык җитми, һай, җитми. Бу — чир, бу — бәла...

Инде кузгалмакчылар иде, әллә каян Шамил Усманов килеп чыкты. Әхмәтсафа аны шундук танып алса да, якын килергә батырчылык итмәде, әмма Усмановның:

— Иртәгә Казанга Горький килә, бөтен шәһәрне аякка бастырырга кирәк, егетләр! Онытылмаслык итеп каршы алуны оештырасы иде. Сәйдәшне эзлим, корт чаккыры, аяклар калмады, кибәнгә төшкән инәмени?! Гастроль-мазарга китеп бармагае. Оркестр булмаса, эш харап!..— дигән сүзләре ишетелде.

— Сәйдәш театрда,— диде Хәким Сәлимҗан.— Яңа гына килеп калды.

Усманов, артык бер сүз дәшми, кырт борылып, килгән якка чапты.

...Каргалы мосафирлары тулай торакка юл тоттылар. Инде Әхмәтсафаның башында бер генә уй бөтерелә: «Горький Казанга килә! Максим Горький, дөньяга танылган мәшһүр язучы килсен әле шәһәргә! Ничек шатланмыйсың ди монда? Күреп калырга кирәк, һичшиксез, күреп калу чарасына керешергә кирәк!»

* * *

Тулай торакка кайтып, бераз тын алгач, Әхмәтсафа, Рабига белән Бибкәйне ияртеп, курсташы Вилдания Хәсәнова бүлмәсенә юнәлде. Вилдания аксыл озынча йөзле, коңгырт чәчләрен кыска итеп кистергән, чандыр гәүдәле, чәчелмичә, сибелмичә, бар күңелен укуга биргән кыз, бәхеткә, үз бүлмәсендә булып чыкты. Әхмәтсафаны күрүгә, күзендә тояк уйнап алды, очкыннар чәчелеп киткән иде, егет артында тагын ике кыз күренгәч, шул мәлдә үк йөзеннән күләгә йөгереп үтте.

Әхмәтсафа Вилданиянең үзенә ничектер сәеррәк каравын тоеп йөри иде, юкка булмагандыр, ахры, күңелендә ниндидер сер йөрткәндер, бүлмәсенә ят кызлар ияртеп керүен өнәмичә, авызын бөрештерде, күзләрен чепиләндереп, бер егеткә карап алды, аннан кызларга күз салды.

Чибәр иде кызлары. Шул арада Вилдания үзенә таныш булмаган кунакларга бәя биреп тә өлгергән иде инде. Әхмәтсафа үзе буйга озын булмаса да, нык бәдәнле, чүкеч кебек таза егет, ни җитте кызлар ияртеп йөрмәс. Кызларның яшькә олырагы гадилеге, ихласлыгы белән күңелне җәлеп итәрлек шул. Бөрчекле күлмәге гәүдәсенә шулкадәр килешә, кыздан ниндидер сафлык, садәлек бөркелеп тора. Озын чәчләре дулкынланып иңнәренә төшкән, үзе оялчан, җитмәсә. Хәленнән килсә, Әхмәтсафаның киң җилкәсе артына посып, дөньяга күз дә салмый тик йөрер иде. Икенчесе исә сусыл чия иренле, алсу йөзле искиткеч чибәр яшь кыз бала. Әхмәтсафага охшаган, сеңлеседер, мөгаен, алай тартынуны да белеп бетерми бугай, әнә абыйсын этеп-ерып, кыр кәҗәсе елгырлыгы белән бүлмә эченә үтте, бүлмә хуҗасының рөхсәтен сорап тору кая — карават өстендә яткан киергегә тартылган чигүне алып, кулында әйләндерә дә башлады. Вилдания сизгер күңелле, һавадан йолдыз чүпли торган кыз түгел, һәрхәлдә, тиз аңышты, мондый кызлар ияртеп йөргән егеткә аның кебек сазап килүче кыз нигә? Ул мизгел эчендә тынычланып калды, үз-үзен кулга алып, көтелмәгәнчә ачылып китте, елмаеп, кунакларны түргә үтәргә өндәде:

— Ник өелештегез ишек төбенә? Үтегез, утырыгыз...

Бу сүзләр Бибкәйгә кагылмый иде инде. Ул караватка менеп кунаклаган да авызын ерып утыра. Вилдания аңа күз төшереп алган иде, көлеп җибәрә язды. Чак тыелып, курсташына дәште:

— Бер дә күзгә-башка чалынмадың, Әхмәтсафа, әллә быел килергә уйламый микән дип йөри идем, ә син мут егет, поезд кебек, бер вагон кызлар тагып йөрисең икән әле.— Вилданиянең тавышында бернинди киная юк, ул инде егетнең, чыннан да, үзенә мәңге тәтемәячәген төшенгән иде. Нәфес — шайтан, акыл — иман, дигәннәр. Кыз акылны нәфескә баш итеп куярга өлгергән иде инде. Ул тыңлыйм, ни йомыш? дигәндәй, буйсынучан кыяфәт белән Әхмәтсафага текәлде.

— Ярлының сүзе ертык турында булыр, һаман да бер сүз, Вилдания, кызларыма төн йоклап чыгарга урын кирәк,— диде Әхмәтсафа, беркавым хәл-әхвәлләр сөйләшеп утырганнан соң.

...Вилдания янына мондый йомыш белән кергәләгән иде инде ике-өч мәртәбә. Җамал, йомышы төшеп, Арчадан Казанга килсә, Әхмәтсафа янына керми калмый, кайбер чакта, бик соңга калынса, кунып та киткәли иде. Әле яз көне кинотеатрларда гөрләп барган «Броненосец Потемкин» дигән кинолы карарга дип килгән иде. Әхмәтсафа белән икәүләп кинога бардылар, Җамал гел егеткә сыенып, колагына йом-

шак сулышын өреп, ниндидер шаян сүзләр әйткәләп утырды. Корабны кулга төшереп, матросларның шатланып, җилкенеп йөргән кадрларны күргәч, тамашачылар түзми кул чабарга тотындылар, берара тамаша залы гөр килеп алды. Җамал исә кинода барган вакыйгаларга күз дә салмый, һаман егеткә сыена, тыйгысыз дәртен Әхмәтсафага да күчерергә тырыша иде. Тегесе исә моны сизмәмешкә сабышып, экран эченә кереп йотылган сыман утыруын белә. Җамалның үкерепләр елап җибәрәсе килде әлеге минутларда.

Сеанстан соң, экранда күргәннәрен өр-яңадан күңеленнән кичереп, кинода барган вакыйгалар тәэсиреннән аерыла алмый исәнгерәп кайтып барган егеткә бәйләнеп тә азапланды Җамал.

— Юкка килдем, ахры, бүген...— диде ул, әрнегән шикелле.— Өйрәледә бер кич, боткалыда ике кич гомер үткәреп йөрүче әрсез алабай сыман инде үзем. Чүриледә эшем калды өелеп, Арчада, волкомда, бетермәгән эшләрем бар иде. Ә мин, җүләр, монда йөрим, юкны бушка аударып...

Әхмәтсафа дәресләрдән соң тамак та ялгап өлгермәгән иде. Ул көнне киногa җыенмаган да иде бугай. Җамал шаулап килеп керде дә:

— Кинога алып бар! — дип ялына, тәкатьсез рәвештә бүлмә буйлап бөтерелә башлады.

Егет, ничарадан бичара, билет юнәтергә чыгып чапты. Нәрсәгәдер пошынып, бәлаләп барган Җамалга Әхмәтсафа сәерсенеп әйтеп ташлады:

— Аңлап бетермим мин сине бүген, Җамал. Үзең кино дип авыз суы корыттың... Ошамады дисәң, көфер сүз булыр. Шундый шәп картина... Әле ярый килгәнсең. Карарга җай чыкмый йөри иде.

— Авызыңнан җил алсын. Нишләп ошамасын кино? Ошады-ы...— диде Җамал чытлыкланып. Болай кылану аңа килешми иде...

Җамал — революция тудырган яңа тип кеше, анда һәрчак көрәш дәрте, аңа кем беләндер тартышырга, шушы тартышта үзенекен эшләп калырга кирәк. Моның ахыр нәтиҗәсе ничек булыр, гомумән, мондый юл белән бару аны кая китереп чыгарыр — анысын уйлап тормый. Ул башкаларның аның ихтыярына буйсынуын тели, әгәр каршылыкка очраса, артын-алдын уйлап тормый, даулаша башлый. Барып чыкмаса — фаҗига, ул моны кабул итә алмый. Юк, ул чигенми, үзен яклардай кешеләрне барлый башлый, коллектив туплый. Ниндидер шайтан колагына пышылдаган кебек, бер нәрсәне тоя — коллектив акыл теләсә нинди акылсыз эшләрне дә җиңел генә һәм рухи тетрәнүләрсез эшләп ташлый ала. Кем өстә — шул көчле. Җамал югарыга омтыла,

белә — өстә кем генә утырса да, түбәндәгеләрнең иреген чикләү белән шөгыльләнәчәк. Теләсә нинди хакимият өчен уртак сыйфат һәм иң прогрессив дип саналган хакимият өчен дә хас бу. Җамал моны аңлап бетермәсә дә, тоя. Аның үз ирегеН теләсә кемгә чикләтеп, йомылып яшисе килми. Юлына кем очраса да, аны буйсындырасы, үз көенә биетәсе килә. Ул үзен җәмгыятькә көчләп тагарга маташа, андыйлар исә тора-бара тиранга әверелә. Тик менә Әхмәтсафа белән генә барып чыкмый. Җамал сизә, егеткә мәхәббәте уянды аның, җанда мәхәббәт кабынган мәлдә күңел күзе сукырая. Мәхәббәт — маңгай күзе җимеше булса да, аның өчен җан газаплана. Егет алдында Җамал җебеп кала. Какшамас большевик катылыгы югала. Елыйсы килә башлый. Елау — большевик холкы өчен хурлыклы гамәл. Менә бит, Әхмәтсафаны пыр туздырып ташлыйсы урынга, ул һаман аңа сарылып, чытлыкланып кайта. Җамал мондый чакта үзен-үзе кулалмый, үзеннән чиркана, нәфрәтләнә иде.

Әхмәтсафа хатынның җанында барган тартышны аңлый кебек.

Каргалыда укыган чакта, Мифтах хәзрәтнең һәрдаим кабатлый торган сүзе бар иде: «Тартышуда гына табарсың үз хакың! — ди иде, ниндидер хыялый җилкенү белән. Аннан өстәп куяр иде: — Балалар, моны әдәбият күгемездә балкып кабынган Гаяз хәзрәт Исхакый әйтә. Андый кешеләремез бар чагында безнең милләткә килер ул якты көннәр. Килер, боерган булса. Әле татар милләтенең үз сүзен әйтер көннәре алда. Танытачак әле ул үзен дөньяга! Гаяз хәзрәт, Тукай, Риза хәзрәт Фәхретдин, Фатих Әмирхан, Галимҗан Ибраһим... Һәй, саный китсәң, азмы бөек затларымыз?! Мондый гүзәл фикер ияләре белән теләсә кайсы милләт горурлык ләззәте чигеп йөрер иде. Болар бит соңгы дәвердә мәйданга чыккан каһарманнарымыз. Аңлап, кадерләрен белеп бетермибез. Хәер, Тукай хәзрәтләре моны үзе үк әйтеп биргән. Тыңлап карагыз әле, балалар, күңелегездән үткәреп тыңлагыз:

Бармыни бездә гомумән чын кеше кадрен белү?!
Без аны кайдан белик, мискин үлеп аңлатмагач?!

Бу сүзләрне әйткәндә, аның күңелендә нинди өермәләр уйнап узгандыр, күзеннән нинди ачы яшьләр тамгандыр? Бүгенге хәлемез безнең шулай, балалар. Әмма килер көн, чыгар кояш, хөрмәткә лаек затларымызны берәмтекләп бармыз, аларның авызларыннан чәчелгән җәүһәр-мәрҗәннәрне кадерләп җыеп, милләтебезнең акыл китабына алтын хәрефләр белән язып куярбыз. Әлегә без моңа әзер түгел, татарның фаҗигасе бу... Гасырлар буе милләтемезнең иң

алдынгы, иң гаярь, иң тапкыр, иң зирәк затларын чүпләп килгән карагруһ баскынчылар. Вагайган халык, идеалын җуйган. Денем өчен түгел, көнем өчен дип яши башлаган...— Мифтах хәлфә кайвакыт үзенә карап авыз ачып тыңлаган балаларны да онытып җибәрә иде бугай, үзалдына уйлаган-сөйләгән кешегә охшап кала иде.— Яшәүме соң ул? Җан асрау гына бит! Әле алда күпме эшләр тора безнең. Күп казганырга кирәк әле безгә... Белмим, морадка ирешеп булырмы, асыл максатларымызга өлгәшербезме? Җанда мең еллар тәрбияләнгән иң гүзәл сыйфатларын җуйган хәлдә басты егерменче гасырга халкымыз. Хөсетлек, бер-береңә яла ягу, ышанмаучылык, көнләшү — менә нәрсә үтерә безнең милләтне. Егерме беренче гасырга исән-имин барып җитәрбезме? Җитсәк, нинди хәлдә, нинди төстә? Нинди иман белән? Шәхескә карата битарафлык — татар белән урысны якынайта торган төп сыйфатларның берсе. Уйлый башласаң, башлар чатный. Бер сораугa да җавап таба алмый изаланам...— Аннан кинәт исенә килеп, балаларга дәшә: — Сез алай булмассыз бит инде, балалар? Начар сыйфатларны ияртмәссез үзегезгә диюем?»

Шәкертләр беравыздан:

— Юк, без алай булмабыз! — дип ярып салалар.

Мифтах хәлфәнең йөзе яктырып китә, ул дәртләнеп сабак өйрәтергә тотына.

Аннан ара-тирә кабатлый торган сүзләрен хәтердә яңартып ала.

— Ходай сөекле бәндәсенә иң олы сынау җибәрермен, дигән. Мөгаллим, хәлфәләр менә шушы сынауга дучар булган затлар инде. Фани дөньяда җәзага дучар ителгәннәр, дисәң дә ярый... Башкаларга аң-белем, тәгълим-тәрбия бирә торгач, хәлфә үзе зәгыйфьләнә, сула, берзаман аңа үз шәкертләре үк көлеп, өстән карап үтә башлыйлар.

Юк, үкенеп, сыктап түгел, болай гына сөйләнеп ала ул.

Әхмәтсафаның күкрәгенә ниндидер төер килеп утыра иде мондый чакта, нигәдер бик кызганыч сыман тоела иде хәлфәләре. Кызык, кешенең тормышыннан бер генә көнен дә, сәгатен дә, минутын да алып ташлап булмый икән. Гомернең һәр мизгеле җанда сулкылдап яткан кебек... Менә бит кайчангы хәлләр хәтердә уянып, күңелне актарып ташлады.

Җамал, егетнең уйларын укып барган диярсең, дәшмитынмый, үз эченә йотылып барган Әхмәтсафага нык кына төртеп алды:

— Әй, шәкерт, кайда йөрисең син, ә?

Егет сискәнеп китте.

Кемне дә булса сискәндерә аласың икән, димәк, әле син

бөтенләй үк бетмәгәнсең. Җамал, үз шаяртуыннан күңеле булып, көлеп җибәрде.

— Аяктан калдың бит, өстерәп алып кайтып барам, үзең сизмисең дә.

— Гафу ит, Җамал, онытылганмын икән шул...— Әхмәтсафага кыен булып китте. Уе әллә кайларга йөгереп алды. Ул болай уйга бирелүнең сәбәпчесе — Җамал үзе икәнен әйтеп тормады инде, билгеле. Кызганычка каршы, яңа зыялылар, милләтнең белдекле оланнарын тәрбиялим дип йөргән Мифтах хәлфәләренең өметләре акланмады бугай шул. Тартышуда үз хакын табу мәсьәләсен яңа буын башкача аңлый. Моның иң ачык мисалы — Җамал буладыр да. Аның идеалы — хатын-кызның бәйсезлеге, буйсынмас холыклы, нык рухлы булу. Рух — мәсләк дигән сүз. Ә Җамалның мәсләге нинди? Монысын инде Әхмәтсафа һич аңлый алмый. Ниндидер чиксез бер омтылыш. Дөньяда төпсез күктән башка һәрнәрсә чикле. Кая ашкына бу хыялый хатын, аңламассың...

— Гафу ит, имеш. Таптың сүз! Ник дип әле юк кына нәрсә өчен дә гафу үтенеп маташасың? Һай, бу укыган миңгерәүләрне...— Җамал аны үчекләп алды.— Рабиганы уйлап барасыңдыр әле. Каргалыда калган былбылыңны,— диде ул, үчекләвен дәвам итеп.— Рабига яңа тормыш төзи алырга сәләтле түгел ул. Юкка күңелеңне саласың син аңа.

Егет бу кадәресен үк көтмәгән иде.

— Ник алай дисең? Рабига акыллы кыз. Бәлки, нәкъ шундый кешеләр кирәктер безгә хәзер. Арт белән киртә җимереп йөрүчеләр чоры үтеп бара.

Җамалның җене чыкты.

— Тәвәдәй буй биргәнче, төймәдәй уй бир. Нәрсәгә генә укыта торганнардыр сине...

— Беләсеңме, Җамал, сиңа да укырга кирәк. Кабатлап әйтәм, революцияне ясаган иптәшләрнең күбесенең анкетада күрсәтерлек бер генә белеме бар иде — төрмә университеты. Әмма ил үскән саен, төрмәдә җыйган белемнәр генә җитми. Илнең нигезе нык булсын дисәң, аны салуны белемле кешеләргә тапшырырга кирәк.

— Барына фатиха, югына әттәхият! — Төксе генә җавап кайтарды Җамал.— Белемем үземә бик җиткән. Кесәләрендә өчәр уку йорты тәмам иткәнгә язу йөрткән кешеләр дә минем белән сөйләшергә шүрләп торалар әле,— диде ул һаваланып.— Мин аларны чәйнәп кенә төкерәм, ачуым чыкса.

— Анысы булыр. Моның өчен белем кирәкми бит. Әмма алга карап яшәргә кирәк. Надан кеше генә киләчәк хакында уйланмый. Их, киләчәк! Нинди булыр ул, ә, Җамал?

— Җитте, шундый матур иде кәефем, күчәр дегетенә әйләндердең, чистый.

Җамал кебекләрне хак юлга чыгарам дип тартышу көлке икәнен аңлап алды егет. Әхмәтсафаның сүзләре, тәгәрмәчкә уралган чытыр кебек, Җамалның саруын кайнатып кына баралар иде. Кеше җанының гариплеге — башкалар җанын аңлый, тоя белмәү.

— Ачуланма инде, Җамал, кинодагы хисләрдән айнып бетеп булмый. Көчле эшләнгән.

Җамал тагын Әхмәтсафага елышты.

— Ташла инде шул акыллы сүзләреңне... Хәер, киләчәк дип юкка гына чәбәләнмисең син, зур кеше чыгар синнән, түрәләрнең түрәсе булырсың.

Егет көлеп җибәрде.

— Каян алып әйттең әле син моны?

— Гел үзеңнекен тукып барганга әйтәм... Түрәләр шулай бит алар. Башкаларның үзләре ишетәсе килгәнне генә сөйләүләрен телиләр. Кинодан чыкканнан бирле мине акылга китермәкче булып азапланасың.

— Ничек уйлыйм, шулай сөйлим инде. Үлемнән качып котылып була, үзеңнән качып та котылып булмый. Акыл кешене биеклеккә әйди, йөрәк сабырлык читлегенә ябып куймакчы, тыйнаклык мокытлыкка өстери. Кызык инде кеше дигәнең, һәрнәрсәнең чиген-чамасын белү кирәк тә, барып чыкмый шул алай. Чик-чаманы югалтабыз да куябыз. Гаҗәп...

— Мин менә бернәрсәгә дә гаҗәпләнмим, беркемгә ышанмыйм...

— Син моны үҗәтләнеп кенә әйтәсең ич... Гаҗәпләнә, соклана белмәү — бәхетсезлек. Игелекле, матур кешеләр азмы дөньяда? Ничек сокланмыйсың, ничек ышанмыйсың аларга?

Җамал, көлеп, егетнең беләген чатырдатып кысып алды.

— Җитте сиңа, миемне кайнатып чыгарасың инде. Кая, табып бир шундый әүлияне! Матур да булсын, игелекле дә булсын, изге дә булсын. Ышанмыйм мин моңа! Матурлык сокландыра, ышандырмый. Бу сөйләшүгә нокта куярга кирәк. Җитте! Үзең әйтмешли, чаманы югалтасың. Аннан мин бөтенләй башка нәрсә хакында уйлап барам әле...

— Нәрсә хакында?

— Бүген мине кайда кундырып чыгарасың? — диде Җамал, пышылдап кына. Кайнар сулышы янә Әхмәтсафаның колак яфрагын көйдереп алган сыман булды.

— Табарбыз, күңелең киң булса, кайда да сыярсың! — дип шаяртты егет.— Бер кичкә кер мичкә...

Җамал моны үзенчә аңлап, тәненнән җиңелчә калтырану уйнаклап үтте.

— Шәп егет син, Әхмәтсафа!

Әхмәтсафа исә Җамалның Рабигага карата рәхимсез сүзләрен исенә төшереп, эчтән рәнҗеп тә алган иде, яшь хатынның кайнарланып пышылдаган сүзләрен ишетмәгәнгә сабышты.

Тулай торакка кайтып, үзенең инде берничә мәртәбә кунып чыккан Вилдания янында төн үткәрәсен белгәч, Җамал, бүселеп, Әхмәтсафага зәһәр генә карап алды.

— Ну шушы сала гыйбадларын! — диде ул, үртәлеп һәм, артык бер сүз дәшмичә, Вилдания бүлмәсенә теркелдәде.

Төн буе җүнләп күзенә йокы кермәгән Җамал таң сызылу белән Арча поездына йөгергән, Әхмәтсафа исә дәресләргә ашыкты, яңадан шактый күрешми тордылар алар. Җамал бик нык үпкәләгән иде егеткә, каникулга кайтып китәргә җыенып йөргәндә, кисәк килеп кереп, артык сүзгә керешми генә, Каргалыдагы әнисенә күчтәнәчләр калдырып чыгып китте...

...Вилдания тыз-быз килеп чәй әзерләп йөри.

Чәй әзер булгач, Әхмәтсафа авыл күчтәнәчләрен дә алып килде, аңа моңарчы егетләр бүлмәсендә утырып торган Шираз да ияргән иде.

— Монысы кем була тагын?

— Каенишем! — Әхмәтсафа тартынып торган үсмергә карап күз кысты.

Шираз гәүдәгә Әхмәтсафаны үтеп бара, таза, нык бәдәнле, һич тә быел гына җиде сыйныфны тәмам кылган димәссең, авылда эшләп, чуендай кара янган сөйкемле егет иде ул.

— Бәр-рә-мәч, мин һаман искә алмый йөрим икән, әллә өйләнеп килдеңме син? Һәй, Әхмәтсафа, үткен дә үзең, нинди кызны эләктергәнсең! — дип көлә-көлә, тимер кружкаларга чәй агыза башлады Вилдания. Үзе инде хәзер аерата бер кызыксыну белән астан гына Рабигага карап-карап алгалый.

— Ә кәк же! Күпме өйләнми йөрергә була, кадерсезләнеп?

— Кадерсез халыкның кадерсез балалары инде без...— диде Вилдания.

Әхмәтсафаның шаяртуын килештермичә, Рабига кулларын чәбәләндереп алды.

— Юк, юк, Вилдания, алдаша ул. Нинди өйләнешү ди ул?! — Рабига кызарып чыкты. Ник алай сөйләшәсең инде дигәндәй, шелтәле күз сирпеп алды Әхмәтсафага.

Вилдания, сертотмас үрдәк, сөйләнә бирә:

— Кызлары күп аның,— диде Әхмәтсафага төрттереп.— Әле Арчадан Җамал дигәне килеп йөрде кыш буе. Син ачуланма, егеткәем, мин дөресен әйтәм, әгәр Рабига ярата икән, мондый вак-төяккә генә игътибар итмәс. Шулай бит? Куркасы юк, гел минем янда кундырды Җамалны. Үзем шаһит.— Вилдания хихылдап көлгән булды.

— Җамал — минем апам ул, бертуган апам,— диде Рабига акрын гына.— Башка туганнарыбыз юк бит Казанда, Әхмәтсафа янына килеп йөри инде.

— Юкәдә икән чикләвек, малайкаем, боларның араларында ни бар микән соң, дип баш ватып йөргән булам мин тагын. Сез инде, алайса, күптән танышлар, кушылып кына җитә алмыйсыз. Ник сузасыз, күпкә киткәч, кызыгы калмый ич анының?!

— Сүзләр хуш та, кесә буш бит, Вилдания. Рабига эшкә урнашсын, минем дә мактанырлык чамам юк. Җайлашып кына киләм шәһәр тормышына. Бераз гына сабыр итик, ул чагында оя корып та җибәрергә булыр.

— Әйтәм бит, уен-муен уйнап йөрмисез икән! Кыек атсам да, туры тигердем, ахрысы, тәки сер төенегезне чиштем. Бер дә аптырап тормагыз, үзем шаһит булам загста, өйләнешегез генә! — диде ул һәм, каударланып, чәен уртлап куйды.— Нинди бәхетле сез! — Бу сүзләрне чын йөрәктән, әчке сагыш белән әйтте ул, күзләреннән моң бөркелеп чыкты.

...Икенче көнне иртүк Горькийны каршы алырга бару иде исәпләре. Җыена башладылар. Тулай торак гөр килә, кайда, кайчан киләчәк бөек язучы — барысына да билгеле. Эчендә җаны булган кеше түзеп бер читтә калырлыкмы соң?! Иртәдән ду купты студент халкы, өс-башын рәткә китергән була, төзәнә, ясана, ыспайлана. Мәхшәр купкан диярсең. Әхмәтсафалар көч-хәл белән җыенып чыгып киттеләр. Җитмәсә, тулай торак хуҗасы — комендант бәйләнеп азапланды, Әхмәтсафаны өч кенә сәгатькә кизү торырга ризалаштырмакчы булып, ниләр генә кыланмады. Имеш, кизү торырга тиеш Сәгыйтовның үтә ашыгыч эше килеп чыккан, аны алыштырырга кирәк. Чыккан ди, чыкмый. Горькийны күреп калырга ашыга. Иртәдән бирле түбән курста укучы бер егетнең чалбарын сорап, тегенең бәгыренә төшеп йөри иде. Горькийның Сәгыйтов кигән чалбарда ни эше бар, ямаулы кием күрмәгәнме, үзе андый кием кимәгәнме ул? Кизүлеген икенче берәүгә ташлап, зур кешеләр арасында кайнашасы, үзен күрсәтеп каласы килә анының, шул гына. Өлешеңә төшкән көмешең, дускай, бигайбә, чиратың җитеп, кизү булырга язган икән бүген, торасың инде. Мондый чакта кем генә сине Горькийны каршыларга җибәреп, үзе авыз күтәреп тулай торакта калыр микән?

Шулай ыгы-зыгы килеп йөргәндә, җай табып, аны Вилдания бер читкәрәк чакырып алды һәм кулына дүрткә бөкләнгән кәгазь тоттырды.

— Өченче көн генә бер кыз килеп, сине эзләп йөргән иде. Шундый чибәр, мин сиңа әйтим. Үзе ачык, сөйләшергә ярата. «Бергә укыдык, дуслар идек»,— диде. Сиңа шушы язу-

ны калдырды. Ачулансаң ачулан, Әхмәтсафа, миңа ул кыз ныграк ошады. Бусы да әйбәт. Тик аз сөйләшә Рабигаң...

Хат Заһидәдән иде. Һәм ул Әхмәтсафаның кулын яндырып алган кебек булды. Маңгаена тир бәреп чыкты. Укымыйча йөрәк түзми, кызыл почмак түренә үтте дә, тәрәзә янына басып, тиз генә хатка күз йөртеп чыкты.

*«Заһидәне онытып барасыңдыр инде, егеткәй. Миңа рәнҗеп йөргән чакларың да булгандыр. Яшь чакта җирдә йөрмәдем бит. Инде җиргә төштем. Як-ягыма карыйм, гомеркәйләр искән җил икән, сызгырып үтеп бара яннан, кешедә бер гаме юк. Мин исә һаман ялгыз. Үзем медтехникум тәмамладым. Быел институтка керергә җыенам.*

*Теге вакытта Бохарада очрашкан көнне искә алам да үкенеп туя алмыйм. Яннарыңда каласы гына иде бит. Ялгызыңа кыен булгандыр инде. Хәер, син түзем, көчле, нык холыклы кеше шул. Менә исән-имин кайтып җиткәнсең, престижный уку йортына кергәнсең. Зур кеше чыгачак синнән, егеткәй. Заһидә әйткән иде диярсең. Яннарыңда кала алмадым шул... Мин ул үзбәк якларында йөреп, туеп беткән идем шул инде. Газиз әнкәем кабердән торып үгетләсә дә, белмим, калыр идем микән анда. Ул чакта башым тәмам әйләнеп беткән иде. Трахома, корчаңгы, бет... Әрсез үзбәк адәмнәренең юлыма төшеп, өченче, бишенче хатынлыкка эләктереп калырга маташулары... Бар күргәнем шул булды. Җык чиктем. Җай чыгуга, алны-артны карамый Казанга качтым. Хәзер инде сабырландым. Яшьлектәге җүләрлекне искә алам да үземне битәрләп туймыйм. Кирәк бит, Тукташ дип хыялланып йөр, имеш. Аңа тиң идемме соң мин? Шуны да аңларлык булма инде. Көлеп үләрсең, валлаһи. Боларны нигә язам соң әле мин? Болай гына. Күрәсем килгән иде, сөйләшәсе килгән иде. Килдем, син авылда икән әле. Кайчан килеп җитәрсең?.. Килсәң, нинди уйлар белән килерсең, анысы да билгесез. Шулай да сиңа хат калдырырга булдым. Бәлки, күрешергә насыйп булыр. Соңгы араларда еш хәтергә төшәсең...*

*Каян эзләп тапкан, дип аптырама. Синең хакта миңа Сәгыйтов әйтте. Бергә укыйсыз икән. Аның белән татар яшьләре клубында, әдәби кичәдә очраштык. Кутуй белән Туфан дигән шагыйрьләр оештырган кичә. Шәп шагыйрьләр, шәп егетләр. Кызлар биһуш инде икесенә дә. Сәгыйтовка нәрсәдер ошамады, сәхнәгә менеп, икесен дә «туналы» гына. Анадан тума калдырды. Вәт тел кешедә. Каян табып бетерә бу кадәр ачы, әремле, үт суы кушылган сүзләрне?*

*Сәхнәдән төшкәч, янына бардым. Куркып кына бар-*

*ган идем, сәхнәдәге зәһәрлегенең эзе дә калмаган, йомшак кына сөйләшә. Синең адресыңны да ул бирде. Ә шулай да явыз кеше бугай ул. Саграк бул аның ишеләрдән. Очрашасың килсә, кил, шат булырмын...»* — дип тәмамлаган иде хатын Заһидә. Адресын да күрсәткән.

Бу хат бөтенләй аптырашта калдырды Әхмәтсафаны. Вилдания берничә мәртәбә кабатлаган «чибәр» дигән сүз дә үз эшен эшләде бугай, йөрәк түрендә утлы нәрсә кузгалып алды, канына кайнарлык йөгерде. «Һи, шайтан кыз, каян килеп чыктың син тагын? — дип битәрләде эчтән генә Әхмәтсафа Заһидәне.— Оныткан идем бит инде, җанымда сиңа тары ярмасы кадәре дә урын юк иде». Хатны укып чыкканчы җебеп, боламыкка әйләнеп калды күңеле, тез буыннары сыекланды әнә. Кузгалып китә алмый. Ул кәгазьне чалбар кесәсенә салды да, йөзендәге аптырау галәмәтләрен җуярга теләгәндәй, ике кулы белән нык кына битләрен сыпырып алып, үзен бүлмәдә көтеп утырган Рабига янына ашыкты.

Күрәсең, Рабигада хатын-кыз сизгерлеге үтә көчледер, Әхмәтсафаның йөзенә күз ташлау белән имәнеп китте, тавышын күтәрмичә:

— Ни булды, Әхмәтсафа, төсең үзгәргән? — диде.

Әхмәтсафа, игътибар итмә дигәнне аңлатып, кулын гына селтәп алды.

— Юк ла... Тулай торакта беркем дә калмый, дип, кизү калырга кыстап йөриләр. Таптылар бер кеше... Ачуым килде...

— Син нәрсә диден? — Рабиганың күзендә курку чагылды, бөек язучыны каршы алу чарасына бара алмый калудан йөзенә гаҗизлек чаткылары сибелде.

— Җүләрме әллә мин?! — диде Әхмәтсафа.— Кемгә тиеш, шул калсын кизүдә. Баш бутап йөрмәсеннәр.

— Кемгә тиеш соң?

— Кемгә булсын, Сәгыйтовның чираты инде. Ул болгатып йөри...

— Ачуланмасалар ярый да инде үзеңне.

— Сәгыйтовның сүгенмәгән чагы юк аның. Беренче тапкыр гына юлга аркылы төшүе түгел...— Егетнең ачуы кабарган иде. Инде дә килеп бу Заһидәсе каян килеп чыкты тагын... Сәгыйтов юкка гына бирмәгән аңа адресны. Ул белә иде бит, Әхмәтсафа өйләнергә җыена, сөйгән кызы бар. Аның өчен Әхмәтсафа белән Рабига арасындагы мөнәсәбәтләр һич тә яңалык түгел. Әле Рабига институтка килгән көннәрдә үзе дә кыз тирәсендә чуалып алган иде. Кыз бер дә ыркым бирмәгәч, ачуланып: «Харап икән!» — дип, кызны тупас кына этеп җибәреп, аңа әйтмәгән сүз калдырмаган иде. Ахырда, кыз һаман бирешмәгәч, «ялыныр чаклар үткән,

үкенерсең, соң булыр» дип, көйләгәндәй иткән дә кул селтәп китеп барган. Бу хакта аңа көлә-көлә Рабига сөйләгән иде. Юк, болай гына бирмәгән ул Заһидәгә адресны. Әхмәтсафа мәхәббәт мәсьәләсендә буталсын, саташсын, акылын җуеп, ахырда барысыннан да коры калсын, дигәндер. Менә хәзер кызның хаты, тәнен пешереп, кесәдә ята. Җанның тынычлыгы югалды да куйды... Укып та тормый ертып ташлыйсы калган икән... Ул, Рабига алдында үзен гаепле сизеп, әкрен генә коридорга чыкты. Кесәсеннән хатны алып, кеше-кара күрмәсен дигәндәй, аны ашыга-ашыга ерткалап, почмактагы чүп чиләгенә ташлады. Аргы башта Сәгыйтовның сүгенгәне ишетелә, мәхәтле, урынына әле һаман кеше таба алмаган, шуңа дулыйдыр.

...Пароход туктыйсы пристань Усиядә, Казанка елгасының Иделгә кушылган урынында. Әхмәтсафалар килеп җиткәндә, анда ерып чыккысыз халык иде. Һәркем алга үтәргә маташа, тавышсыз гына этеш-төртеш, урын өчен көрәш бара. Тырыша торгач, алар да бер җай белән алгарак үттеләр. Бәхет дисәң дә бәхет, алар нәкъ оркестр каршына килеп чыктылар. Оркестр алдында кулларын җилпеп дирижерлык итүче Салих Сәйдәшев шәйләнә. Оркестр әле кызып җитә алмаган, ниндидер көйләрне өзек-төтек уйнап ала да тагын тына. Тагын бер көйне башлый, музыка коралларын кемдер кисәк кенә бер читкә селтәп җибәргән кебек, сәер авазлар чыгарып, янә кырт туктап кала. Туктап торган арада Сәйдәш сабыр гына музыкантларга нидер сөйли, аңлата. Янәдән җилкенеп таягын өскә күтәрә...

Пристаньга якын иркенрәк мәйданда Шамил Усманов, Кави Нәҗми, Гадел Кутуй, тагын берничә яшь кеше тынгысызланып йөренәләр. Алар вәкарь, йөзләре җитди. Яннарына килеп сүз әйтермен димә! Рабигага Әхмәтсафа кемнең кемлеген бәйнә-бәйнә аңлатып торды.

— Кутуй — радио дикторы, атаклы шагыйрь... Теге гел читкә карап сөйләшкәне — Кави Нәҗми. Зур язучы, шагыйрь кеше. Шамил Усмановны кичә күргән идек. Сугыш герое... Атаклы язучы...

Монда да тыныч кына торырга язмаган. Халык җыела тора, әйбәт урын таптык, дип сөенергә өлгермәделәр, кысрыклап читкә этәрә башладылар. Бу әйләнештән котылмасаң, тиз арада әллә кая, койрыкка барып чыгасы иделәр. Әхмәтсафа чамалап алды, кайбер үткенрәкләр тәртип сакчыларына ипле генә:

— Каршы алу комиссиясе,— дип дәшәләр дә алда җыела башлаган кечкенә төркемгә барып кушылалар. Нигәдер берсенең дә кәгазен-пропускысын тикшереп тормыйлар, үткәреп җибәрәләр.

Әхмәтсафа да тәвәккәлләргә булды. Рабиганы кулыннан кысып җитәкләде, Шираз белән Бибкәйгә: «Миннән калмагыз!» — дип ым какты, җитди кыяфәт белән халыкны аралап үтте дә сакчыга шыпырт кына:

— ТКУ делегациясе, каршы алу комиссиясе...— дип, туктап та тормастан, алга үрмәләвен дәвам итте.

— Дүртәүләпме?! — Кычкыра төшеп сорады сакчы.

— Әйе, мең кешелек коллективтан дүрт кеше! — Телгә килгән беренче сүзләрне әйтте егет, сакчыга өстән генә караган булып.

Әрсезлек — ярты бәхет, диләр, номер барып чыкты бит, әй. Сакчы, риза булмагандай:

— Комиссия кешеләренең үзләрен сакларга бер полк кирәк монда,— дип сөйләнә-сөйләнә үткәреп җибәрде. Алар, сихерләнгән кебек, оркестрдан ерак түгел җиргә килеп бастылар. Ул арада Сәйдәш янына атылып Усманов килеп басты:

— Йә, Сәйдәш, берәр нәрсә чыгамы?

— Чыгармый карасыннар! — Сәйдәшнең тавышы шаяртулы иде. Шундук җитдилеккә күчте.— Мондый җаваплы чакта да сынатсак, ни була, бәгырь?..

— Анысын беләм лә...— Монда сүз артык дигәндәй, Усманов ары чапты. Күрәсең, каршы алуга җаваплы кешеләр арасында иң зур вазифа биләүче иде ул. Аның һәрнәрсәдә эше бар кебек, бер минут тик тормый, әле Кутуйлар төркеме янына барып, нидер сөйләп ала, әле кемнедер чакырып алып, аңа кызу-кызу нидер аңлата, ул да булмый, кемнәрдер аның үзе янына йөгерешеп килеп, аннан нидер сорашалар, белешәләр иде.

Әхмәтсафа ирексездән Сәйдәшкә карап алды. Сәйдәшев бу минутларда илаһи күтәренкелек кичерә иде, дулкынланган сыман да. Соңгы мәртәбә күрешүгә дә алты еллап гомер узган, әмма Салих Сәйдәшев артык үзгәрмәгән, шундый ук басынкы, кемгә генә дәшсә дә, йөзендә якты дулкын пәйда була, шул ук вакытта, үз эшенең барып чыгасына тирән ышануыдыр инде, ниндидер җиңеллек күзәтелә хәрәкәтләрендә. Шунсын да искәртте егет, Салих Сәйдәшев карашында ниндидер үзгәлек бар кебек. Ара-тирә күзендә шундый тирән сагыш уйнап ала, ниндидер гаҗәеп зур югалтуга дучар булган кешедә генә була торгандыр мондый караш. Мизгел эчендә ул онытылып китә. Тиз арада үзен кулга ала. Аның күңелендә нидер бәргәләнә, җанында ниндидер яу, көрәш барган сыман. Гәүдәсе монда, күңеле әллә кайларга очына, уйлар еракта, биектә, үзе хыялда әллә кайларга барып кайта шикелле. Нәрсә тынгысызлый аны, җанын нәрсә кыйный, бәгырен ни әрнетә?.. Егет, билгеле, боларны аңлаудан бик ерак иде.

Ниһаять, күптән көткән пароход күренде. Халык өнсез калып, пароходның пристаньга якынлашканын күзәтеп торды да, күңел түрендә кайнаган хисләрнең тулышуына түзә алмый, сакны ярга кысрыклап, тыйгысыз рәвештә пристаньга табан шуыша башлады.

Кемдер ачык итеп:

— Әнә, Горький палубага чыгып баскан! — дип кычкырды.— Шул үзе, Горький бит инде! Мин бит аны күргән идем, ун еллап элек.

Әлеге түземсезләнеп сөйләгән кешегә игътибар итүче дә булмады, сакчылар, беләкләренә кызыл бәйләгән таза егетләр ярдәмендә мыш-мыш килеп, халыкны билгеләнгән чиктән үткәрмәскә тырышып азапланалар. Төркемдәге халык, җәтмәгә эләккән балык сыман, һаман тыгызлана, тагын икеөч минуттан ни буласын искәрешле түгел.

Шул чагында дебаркадер ягыннан йөгерә-атлый Шамил Усманов килеп чыкты. Ул, кулын өскә күтәреп, шундый гаярьлек белән беренче рәтләр алдыннан җилләнеп үтте ки, ыгы-зыгы шундук басыла төште, ташкын басымы күзгә күренеп кимеде.

— Сабыр! — дип кычкырды Шамил Усманов.— Тәртип, тагын бер тапкыр тәртип! Сабыр булыгыз...— Сүзен төгәлләп бетермәс борын, Сәйдәшкә борылды.— Әйдә, Салих, музыка!

Сәйдәшнең бер кул хәрәкәте җитте, оркестр дәртле, ашкынулы музыка уйнап җибәрде. Әле генә барлык киртәләрне җимереп алга томырылырга әзер халык, шушы көй аһәңенә буйсынып, тып-тын калды. Этеш-төртеш, ыгы-зыгының эзе дә калмады. Әхмәтсафа бу көйне кайдадыр ишеткәне дә бар сыман, бик тә гүзәл һәм күңеленә кереп калган таныш бер көй иде ул. Җан гына түгел, гәүдә дә очына, каядыр күккә күтәрелгән сыман хисләр актарыла, серле аһәң җанның иң нечкә кылларына чиртә. Көй үзенә әсир итә, җилкендерә, сафландыра иде, Идел өсләре яктырып, киңәеп китте сыман, күкләр биекләнде, һаман-һаман якынлашып килүче ак пароход музыка тәэсирендә иләс илаһилыкка бирелеп, җиңелчә генә бәллүләп алган кебек хәтта. Бар дөнья шушы якты моңга буйсынды, күзләр пароходта булса, хисләргә көй хуҗа иде. Янәшәдәге ханым, үзе дә сизмәстән:

— Афәрин, Сәйдәш! — дип кычкырды.

Әхмәтсафаның хәтер түре буйлап таныш шәүләләр чагылып үтте. Зиһене уянып, әллә кайчан булып үткән хәлләр — Оренбурның үзәккә үтәрлек салкын кышы, ачлык дәһшәте бумаклаган чорлар исенә төште. Шушы шыксыз чорны нурландырып торган газиз минутларны да хәтерендә яңартып өлгерде: балалар йорты; Шәриф Камалның талчыккан йөзе;

нинди эшкә алынса да, аерым бер җаваплылык белән үтәргә керешә торган Муса: аның арык гәүдәсе, юка йодрыкларын селкеп ала-ала шигырьләрен укуы, йөзендә ике кара энҗе күзләре генә утырып калган үзенең, ә нинди көч яшеренгән аларда, ниндидер серле дәрт, җегәр. Пианино янында утырган ак йөзле Салих Сәйдәшев... Клавишлар өстеннән шундый да җиңеллек белән йөгереп үткән озынча нәфис бармаклар... Әйтерсең инеш өсләп өрфия җил фирүзә дулкын уйнатып уза. Бармакларның йөгерешен шуның белән генә чагыштыра алыр иде Әхмәтсафа. Әлбәттә, үзәкләрне өзеп яңгыраган моңлы көй истән чыкмый. Кая барса да, аңа ияреп барды бугай ул көй... Күңел түрләренә үк үтеп, йокымсыраган җаныңны кубарып, хисләрне йөзләр, күзләр аша тышка чыгарып түгәргә мәҗбүр иткән аһәң онытырлык кына түгел шул. Хисләр чайпалып тулыша да, бермәл ярларына сыеша алмый түгелә, җан сафлана, түгәрәкләнә, күңел бөтенлеккә ирешә бара. Моң тәэсирендә туган хисләрдән дә изгерәк, илаһирак хисләрнең булуы мөмкинме?!

Әхмәтсафа шушы сәер халәттә күпме торгандыр, әмма монда ни өчен килүен исенә төшереп сискәнеп куйды. Шул мизгелдә зиһене дә уянды. Соң, бу нәкъ шул көй — Оренбурда ишеткән, аны әсир иткән моң бит инде. Тик ул инде тагын да камил эчтәлекле, ныклы шәкелгә салынган, дәртле, җиңел төс алган иде, теге чакта Сәйдәш бармаклары арасыннан сагыш түгелгән иде, бүген ул сагышлы аһәңнәр юкка чыккан, өметле яңгырый көй, ышаныч белән сугарылган.

Ул бар дөньяны онытып, авызларын ачып, пароходның пристаньга килеп җитүен күзәтеп торган Рабигага, Шираз белән Бибкәйгә күз ташлап алды. Көлемсерәп куйды. «Их, сез! — диясе килде аның кычкырып. — Күп нәрсәләрне күрмәдегез бит сез, күп нәрсәләрдән мәхрүм. Шушы көйне ишетү өчен генә дә килү кирәк булган сезгә Усия буена. Ә сез нишлисез?.. Авызыгызны ачкансыз да пароходка баккансыз. Хәер, ни дип әйтәсең инде, зур әдип каршыларга төштек ич, Сәйдәш музыкасын сирәкләр генә искә ала бу минутта. Күпләр үзләреннән өч-дүрт адым ераклыкта торган бөек музыкантның барлыгын да онытты шикелле. Шулай инде, без читтән килгәннәргә табынабыз, аларга мөкиббән китәбез, үзебезнең арада йөрүчеләргә кадер дә, сан да юк». Бу сүзләр әйтерсең шушы мизгелдә аның баш миеннән йөгерешеп үтмәделәр, бәлки кемдер кычкырып әйтте аларны. Кем дә түгел, колакка тавышы аермачык чагылды — бу... Мифтах хәлфә тавышы иде. Ул өскә, биеккә менгән дә, һәркайсын акылга китерергә тырышып, җыелган халыкка шундыйрак нәсыйхәт бирә иде. Горький килүен өнәми дисәң... Ул бит Горькийның һәр әсәрен укып, балаларга сөйләп бара иде.

Бөек әдипне хөрмәт итмичә булмый. Бары тик: «Башка бөекләр янында татарымызның бөекләрен дә истән чыгармагыз!» — дип әйтергә, аңлатып калырга омтылуы булды, ахры...

Әхмәтсафа, саташулы уйларыннан тәмам айнып, пароходка табан талпынды, пароход, күп юл үтеп хәлдән тайган дәү бер җанвар кебек авыр мышный-мышный, ара-тирә ян-якка су парлары бөркеп, пристаньга якынлашып бетеп бара иде.

...Еллар үткәч кенә Горькийны каршылаган чакта оркестр беренче мәртәбә Салих Сәйдәшевнең Кызыл Армия маршын уйнаганын белде ул. Әмма бу көй әле яңадан да шактый үзгәрешләр кичергән иде, анысы беренче яңгыраш, халыкка тәкъдим итеп карау гына иде...

...Пароходтан юан баулар ыргытылып, аны тимер бүкәннәргә арканлап әвәрә килгәндә, ягъни әле пароход җүнлерәтле килеп туктарга да өлгермәде, Кутуй, Такташ, Усманов палубага ыргылдылар, үзен каршы алырга килгән халыкны күзләп, бераз югалыбрак калган Горькийны уратып алдылар, күрешү, танышу башланды. Алар тирәсендә яшь кенә егет кайнаша, кулында фотоаппарат, җай чыккан саен, каршы алу мизгелләрен сурәткә алып калырга тырыша иде.

Горький, сакланып кына траптан төшеп, пристаньга үтте, үзен сырып алган яшьләр белән, каршы алу комиссиясе әгъзалары булгандыр инде, бер-ике кәлимә сүз алышты. Нәҗми нидер әйтте, аның сүзләрен Горький аеруча ошатты, ахры, ачылып китеп, елмайды, яшьләр чыр-чу килделәр, аннары язучы эре адымнар белән ярга таба атлады. Сәйдәшев бер хәрәкәт белән оркестрны уйнаудан туктатты, ул да булмады, музыкантлар ниндидер сагышлы урыс көен уйнарга керештеләр.

Бу минутта үз белеклегән Шираз — булачак артист күрсәтте:

— «На дне» пьесасыннан «Кояш чыга да бата» көен уйныйлар,— диде ул, шыпырт кына.

Ә мәһабәт гәүдәле Горький алар белән янәшәдә басып тора иде инде. Ничек алар янына килеп баскандыр, сизми дә калдылар. Шушы бөек язучы белән рәттән басып тор инде. Их, бу югалып кала торган сыйфаты булмаса адәм баласының! Горький янәшәсендә Әхмәтсафа бөтенләй бәләкәйләнеп, кечерәеп калды кебек. Рәхәтләнеп карыйсы, йөз чалымнарын, сөйләшүен, хәрәкәт-ымнарын күзәтеп, хәтергә сеңдерәсе урынга, коелды да төште. Ник бер җүнле уй килсен башка... Ярый әле Сәйдәш музыкасы җанны кузгатып куйды. Бу көйгә Горький үзе дә битараф калмады. Мыегының озын чылгыен төзәткәндәй итеп, оркестрга табан борылды, сәер генә калгынып, тукталып калды. Сәйдәшкә, хуплаган рәвештә, ягымлы елмаеп баш какты. Каяндыр биектән гөрелдәүле тавыш ишетелде:

— Яхшы, бик шәп, якташларым. Сөенеп басам Казан туфрагына бүген...

Кая югалып торгандыр, Горький янына ашыга-ашыга Кави Нәҗми килеп басты.

— Алексей Максимович!..— дип өзгәләнде ул.— Машинага... машинага, зинһар... Сезне көтәләр анда...

Горький, аптырап, Нәҗмигә карап алды, сагышлы күзләре белән янә бер мәртәбә Идел өстен, үзен Казанга китергән «Урицкий» теплоходын күздән кичерде, бер сүз әйтми, озын гәүдәсен алга ия төшеп, ашыкмый гына машинага табан кузгалды.

Оркестр исә сагышлы көйне күңелле, дәртле татар көйләренә алыштырды. Горький халыкка эшләпә тоткан кулын килешле итеп болгап алды да машинага утырды, теге җиңел гәүдәле егет тә аннан калмый, берничә сурәт алгач, Горький янына менеп кунаклады.

— Улы Максим Пешков белән килгән,— диде бер белдеклесе.

Халык арасында сүз йөгереп үтте:

— Малае белән килгән... Максим Пешков... Ул сурәткә төшерә.

Андый чакта табыла бит ул, кайберәүләр, форсат чыгуына куанып, Горький хакында шактый хәбәрдар икәнлекләрен искәртмәкче булып, белгәннәрен чыгарып җилпергә ашыктылар. Кайта торгач, шактый мәгълүмат туплады Әхмәтсафа.

— Ә бит Горькийны башка интеллигентиклар белән илдән куып җибәргәннәр иде,— диде берсе.— Олы пароходны шыплап тутырып озаттылар аларны теге чакта. Ленин үзе кушкан, ди...

— Дөрес тә эшләделәр. Ул сөрсеп беткән интеллигенция белән ни кырмак кирәк? Ленин дөрес әйткән — интеллигенция б... ул! Яңа тормыш төзергә көч, мускул кирәк, интеллигенциянең камыр беләге белән төзеп булмаячак социализмны.

— Алар акыл сатарга оста, эшкә килгәндә — юк.

— Бик беләсегез килсә, Ленин үзе 1921 елда Горькийга илдән китәргә тәкъдим ясый.

— Һе, ясамассың... «Новая жизнь»ны эзләп табып укый иде халык.Ниләр генә юк иде бу гәҗит аламасында. Горькийның «Несвоевременные мысли» дигән язмалары революция өчен иң куркыныч коралга әйләнде ул чакта. Вәт шуннан соң аны Ленин үзе янына чакырып, илдән китәргә кушкан да инде. Әнә хәзер тәүбәгә килгән, ил буйлап сәяхәт кыла. Без, большевиклар, мәрхәмәтле халык бит инде, гафу иттек...

— Итми кая барасың? Бөтен дөнья таный хәзер безнең илдәге уңышларны. Аз гына кырын күз белән карасыннар буржуйлар, кырып-себереп чыгарырга да күп сорамабыз! — дип әтәчләнде озын чәчле егет. — Дөнья хәзер безнең кулда, егетләр. Капитализмның көннәре санаулы. Моны башы булган һәркем белә. Горький да шуңа ышанып кайткан чит илдән. Рәхәт булса, дүрәк түгел бит ул, Италиядән Рәсәйгә кайтырга. Димәк ки, капиталист ипине чамалап кына ашата андыйларга.

— Егетләр, боргаламагыз фактларны, — дип, «белекле»ләргә каршы төшәсе итте өлкәнрәк яшьтәге кеше. — Горькийның алтмыш яше тулып килә. Юбилей. Сталин әйткән: «Чит илдә каңгырап йөрмә. Кайт совет иленә, чын совет гражданы булып яшә, ким-хур булмассың», — дигән. Бөек язучыбыз, күп уйлап тормыйча, ризалашкан да куйган. Сталинның бик тә күңеле булган, диләр...

— Дөрес эшләгән, — диде озын чәчле егет. — Карышып торса, абруена күләгә генә төшәр иде. Әнә халык ничек каршы ала үзен! Мондый кадер-хөрмәтне кем, кайда күрсәтә аңа?

Бәхәс шунда тәмамланды, халыкны төрле тарафларга сузылган Казан урамнары үзенә суырып алып, сафларны сирәгәйтә, эретә бара иде.

Ул көнне Әхмәтсафа Горький булган урыннарга бара алмады. Рабиганы эшкә урнаштырырга, Шираз белән Бибкәйне укырга кертергә кирәк. Үзең йөрмәсәң, каршыңа чыгып: «Әйдә, монда килегез», — дигән кеше юк. Шулай да Горькийның Казандагы һәр адымы хакында белеп торасы килә иде. Кич радиодан Гадел Кутуйның матур тавыш белән соңгы хәбәрләр укуын түземсезләнеп көтеп алды. Кутуй эфирга нәкъ вакытында чыкты.

Горький «Казанское подворье» кунакханәсендә тукталган икән, бүген Зур театрда шәһәр советының киңәйтелгән утырышында чыгыш ясап, үзенең Казанда үткән гыйбрәтле, газаплы тормышы хакында сөйләгән. Шулай да ул кыенлыкларны инде оныткан, Казан турында якты истәлекләр белән генә яши икән хәзер. «Бу сүзләрне ишетү куаныч иде, — дип тә өстәп куйды Кутуй. — Гомумән, аерым шәхесләрнең тарих алдында күргәннәре, кичергәннәре шулкадәр вак нәрсәләр һәм мөһим түгелләр ки, болар хакында артык җәелеп сөйләп тору да урынсыз, диде бөек язучы, — дип сөйләвен дәвам итте Кутуй. — Никадәр хак һәм гадел сүзләр!»

Кутуйның сөенече тавышына чыккан иде... Алдагы көндә Горький хөрмәтенә Яшь тамашачылар театры бинасында концерт була икән. Кутуй, халыкны шушы кызыклы очрашуга чакырып, сүзен төгәлләде.

Әхмәтсафаның уенда Горькийның аерым кеше язмышы хакында әйткән сүзләре бөтерелде. «Чыннан да, аерым шәхеснең язмышы тарих өчен чүп нәрсә генә микән, ә? — дип аптырады ул, бөек язучының сүзләрен шик астына алып. — Кеше язмышына, шәхси кичерешләренә, әрнүләренә, хәтта омтылышларына да битарафлыкка өнди торган сүзләр түгелме соң болар? Шәхес белән теләсә ничек эш итәргә юл ачмыймы бу сүзләр? Шәхесләр булмаса, тарих та юк. Тарих дигәнең табигать сулышы, вакыт агышы гына булып кала. Ә кеше, шәхес күргән газапларны җәмгыять үзе тудырса, нишләргә? Шулай ук җайлы җавап белән генә чикләнергәме? Җәмгыять кылган начар гамәлләре өчен гафу үтенә белмәсә, сабак алмаса, бу — куркыныч. Үз шәхесләрен танымау, аларны инкарь итү, кимсетү, рәнҗетү җәмгыятьнең чиренә әверелсә, нишләргә? Боларны да вак-төяк дип кенә атаргамы?» Кутуйның авызыннан ишеткән сүзләрне бер дә Горький әйткәндер диясе килми иде шул, әмма бу сүзләрне Горький икенче көнне очрашу вакытында да кабатлады... Сәер, сәер иде мондый фәлсәфәне аның авызыннан ишетү. Вазгыятькә ярыйм дип, кыйбласын алыштырган кеше башкаларны ничек яшәргә өйрәтергә хаклымы? Хәер, кеше нәрсәгә булса да ирешү теләге белән ашкына икән, ул ялгышлардан азат була алмый. Бөтен хикмәт шунда, Горький нәрсәгә омтыла, нәрсәгә ирешмәкче?..

Концертка барасыларын белгәч, Рабига, Шираз белән Бибкәй шулкадәр сөенгәннәр иде, насыйп булмады — кечкә табан тулай торакка, гадәтенчә, гаять эшлекле кыяфәттә Җамал килеп керде. Ул Әхмәтсафаның җәйге ялдан килү-килмәвен белешергә дип кенә кереп чыккан икән, инде анда Рабиганы күргәч, бөтенләй телсез калды.

— Син ничек монда? — диде ул, күзләрен чепиләндереп. — Кем сиңа рөхсәт бирде? Каргалыда әнкәйне ялгызын калдырып... — дип сүз башлаган иде, Рабига, сабырлыгын җуеп, аңа каршы төште:

— Әнкәй ялгызы түгел. Аның янына Гариф энебез дә килде быел...

Гариф — төпчек энекәшләре, моңарчы Атбасарда яшәгән иде, Җамал чыгып киткәндә ул кечкенә бала гына, өлкән апасы аның дөньяда барлыгын да онытып бара иде инде. Кече энесенең исемен ишетеп, кисәк кенә төртелеп калды, үзүзен кулга алып, тагын да гаҗәпләнүен белдерде:

— Гариф? Аның белән нишләмәк кирәк? Әнкәй үзе дә кеше өстендә.

— Кеше өстендә түгел! — дип тынычландырды аны Әхмәтсафа. — Безнең Гомәрхан абый быел өйләнеп җибәргән, бик акыллы кыз, әти-әнисе, туганнары юк, апасы белән го-

мер кичергәннәр. Гомәр колхоз оештырып йөри, идарәгә дә якын булыр дип, кәләше өенә күченеп китте. Хәлимә апай, Гариф энекәш безнең өйгә хуҗа булып калды.— Тартай теленнән табар, дигәннәре дөрестер инде, Әхмәтсафа, шаяртасы килеп, өстәп тә куйды:— Без Рабига белән никахта хәзер. Рабиганы Казанга алып килергә булдым. Эш тә табып җибәрсәк...

Җамал чәчрәп урыныннан сикереп торды, Рабигага табан атылды. Күзләрендә зәһәр очкыннар биешеп алды.

— Никах?! — диде ул, ачу белән.— Нинди никах, нәрсә дигән сүз була бу, Рабига?

— Әй, куй инде, Әхмәтсафа, шаяртма...— диде кыз, бәйләнчек Җамалдан котылырга теләгәндәй.— Теленә ни килсә, шуны сөйли...— Кыз, үпкәләгән сыман, читкә карап утырды.

— Бәй, дөресе шул булгач,— Әхмәтсафаның бирешәсе килмәде.— Хәлимә апай, Рабиганы никахсыз миңа ияртеп җибәрмим, диде. Оренбурда муллага барып кайтырга туры килде.

Җамалның битләренә ут кабынды.

— Иске авыздан яңа сүз! Әнкәй сүзен сөйләп, нүжәли никахка бардың, кызый? — Ул Рабигага ябырылуын дәвам итте.— Нүжәли, юрган бөркәнеп, ир астына кереп яту синең өчен бар нәрсәдән кыйммәт — идеал да юк, намус, вөҗдан да?.. Комсомолка, күрегез, ха-ха... Никах укытып йөри, яшь совет гаиләсе төзи, имеш, берәү!

— Ярый инде, Җамал, чәпчемә. Әби... әй лә, Хәлимә апайның сүзен аяк астына салып таптамыйк, дидек. Ни әйтсәң дә әйт, үз башыңа төшкәч кенә беләсең икән аны, бер дә өлкәннәрнең хәер-фатихасын алмый, гаилә корып җибәрәсе килми бит, малай.

— Мәсхәрә!..— диде Җамал, чыдаша алмый.— Син — коммунист, Ленин призывы кешесе. Нинди түбәнлек! Тиз арада партбюрога чакыртып, пешертергә кирәк син егет кисәген!

Әхмәтсафа, эшнең зурга китү мөмкинлеген уйлап, үкенеп куйды. Нигә сүз башларга иде? Акыл телгә күчсә, акыл булудан туктый шул...

— Ни булса булган, әмма бездә бит, син әйткәнчә, юрган астына кереп китү кайгысы юк. Урнашырга кирәк, аннан чын советча никахлашу булыр. Ә мулла никахы хакында күңелле истәлек итеп кенә сөйләргә калыр. Нишлисең, әле халык бар гореф-гадәттән, йолалардан, шәригатьтән аерыла алмый. Ата-ана фатихасы дигәннәре дә бар. Аяк астына салып таптап булмый...

— Сезнең кебек миңгерәүләр бар чагында халык иске-лектән беркайчан да аерыла да алмаячак! — Ул мышык-

мышык елап утырган Рабиганы табалап алды.— Күз яше түгеп утырма! Җыен, мин сине Арчага алып китәм. Монда бер генә көн дә тормыйсың! Ха-ха, совет укытучысы, имеш... Башыңдагы чүп-чар уйлардан арынмый торып, Әхмәтсафа белән көрәшү юк сиңа!

Рабига, тәмам аптырап, бер Әхмәтсафага, бер Җамалга карап алды.

— Арчага? — диде ул, әкрен генә.— Мин бит... Казан... Шираз белән Бибкәй кая кала? Кем карый аларны? — Ашыгып, өтә-төтә сүзләр атты ул, тел ачылганда әйтеп калыйм дигәндәй.

— Башта уйлыйлар аны, никахлы гашыйк! Аптырап торасы юк инде хәзер. Эш үткән. Шайтаныма олаксагыз да, бер-берегезне эзләп табарсыз. Әйдә, сезнеңчә булсын, чукынып китегез, сез өйләнеште дип дөнья бетмәс, социализм төзү уеннан да чигенмәбез.— Йомшара төште Җамал.— Эш юк дип аптырап йөрмә, Казанда синеңише укытучы кисәкләре буа буарлык. Кемгә китереп төртмә — укытучы, мөгаллим булыр. Кем бирсен сиңа Казанда эш. Әмма бар ул! Күпербаш дигән авылда рабфак ачмакчы булып йөрибез. Арчадан ерак түгел, теләсәң, көнендә Казанга килеп, йомышыңны йомышлап китәргә була, Әхмәтсафага да килеп-китәргә уңай булыр, поездга утырып кына килер дә җитәр.— Җамал әйтерсең яңа гына дөнья җимерердәй булып дуламаган, бөтенләй йомшарды. Аның чын күңел халәте дә шушы иде булса кирәк — йомшак, кайгыртучан, ә җикеренүләре, дуамаллыгы фәкать кылану, революцион үзгәртеп кору чорында шулай сөйләшү лязим, йомшак агачны корт баса, синең күңел халәтеңне, асылыңны беркем сизәргә тиеш түгел, йомшаклык күрсәтү — дошман алдында ярамаган кебек, дуслар, туганнар өчен дә зарарлы сыйфат дип, ышанып йөрүдән иде. Аннары Әхмәтсафа алдында үзен күрсәтергә теләү, акланмаган хисләре өчен үч алу тойгысы да кузгалып, җанында гарасат купты, әле анысын да тиз генә басып куеп булмый, үз-үзен кулга алып, эзгә төшкәнче күпмедер вакыт кирәк. Апасының холкын белгән Рабига да эчтән генә Җамалның тынычланганын көтеп утыра иде, яктыра төште.

— Чыннан да, апа әйткәнчә эшләсәк...— дип, Әхмәтсафага күз сирпеп алды.— Әле Казанда эш табып буламы, юкмы? Балалар да үз янымда булыр.— Ул Бибкәйне кочып, аркасыннан сөеп алды.— Аннан авыл авыл инде, ашау ягы да бар бит әле.

Әхмәтсафа телгә килергә өлгермәде, Җамал үзенең фикерен алга сөрүен дәвам итте:

— Шулай булмый соң! Әхмәтсафаның үз акчасы үзенә җитми аның. Кая сезне туйдырып тору.

— Анысын карар идек әле, Җамал. Җан биргәнгә җүн биргән, бер-бер җае чыгар иде.

— Йә-йә, телеңә салынма! Ничек кенә булса да Рабиганы яныңнан җибәрәсе килми синең. Ха-ха...— дип көлеп җибәрде Җамал. Сүзләреннән нинди кызык тапкандыр инде, бер Ходай белә.

— Мин авылга бармыйм!..

Өлкәннәр тып-тын калдылар. Бу сүзне кистереп әйтүче Шираз иде.

— Мин театр техникумына керергә килдем. Авылда сөт белән күкәй ашап утырырга түгел.

Бибкәй пырхылдап көлеп җибәрде.

Җамалның күзләре зу-ур булып ачылды, авызын бөрештереп, күзе белән түшәмне айкап алды:

— Булсалар булырлар икән! Берсендә дә эләккән эш юк бит боларның. Каян керде ул нәмә башыңа, энем? Әртист булып, кәмит уйнап йөреп, яңа тормыш төземәкче буласыңмы, чүлмәк баш!

Сүз иярә сүз чыга, аннан күз чыга. Әхмәтсафа, сүзне артыкка җибәрмәскә теләп, тезгенне үз кулына алды.

— Болай итәбез, алайса,— диде ул, барысын да үзен тыңларга мәҗбүр итеп. Көчле, гайрәтле тавышы гаярь ир-егет икәнлеген сиздереп торганга, Җамал аңа үз итеп, Рабига исә яратып карап алды. Әнисе сүзе келт итеп исенә килде: егет икән, батыр булсын! Җебеп утырмасын, кирәк чагында сүзен әйтә белсен! Әхмәтсафа, үзенә сынап караганнарын искәрмәгәнгә сабышып, дәвам итте.— Җамал дөрес әйтә булса кирәк, әлегә Казанда әллә ни эш кыра алмабыз, якын-тирәдәге бер авылга урнашуны үзем дә хуп күрәм. Яшереп торасы юк, минем башта андый уй йөри иде инде. Рабига белән Бибкәйне Күпербашка озатабыз. ТКУ Арча кантонына шефлык итә, миңа барып йөрергә җай чыгып кына торыр. Ә Шираз Казанда кала. Керсен ул техникумга, үзе яраткан һөнәрен алсын, артист булсын, шәп артист булсын! Минем янда яшәр, аннан күз күрер. Бәлки, техникумның да тулай торагы бардыр...

Барысы да җиңел сулап куйдылар. Шул ук кичтә Рабига белән Бибкәйне алып, Җамал Арчага китеп тә барды. Шираз белән Әхмәтсафа аларны озатып, ярты төндә генә тулай торакка кайтып егылдылар.

...Икенче көн Ширазның документларын техникумга тапшырып үтте дияргә дә була. Документларны алган уңайга күрше бүлмәгә кереп, әңгәмә үткәрүче комиссиягә күренеп чыкты егет. Шигырь сөйләтеп карадылар, этюд та ясап күрсәтте: ул нәкъ Әхмәтсафага охшатып, «итек тегеп» шаккаттырды комиссия әгъзаларын. Сәхнәдә йөреп шактый шомарып та беткән икән: Ширияздан Сарымсаков дигән егеткә

«имтиханнар вакытында аерым игътибар кирәк» дигән тамга салынды. Шираз тулай торакка кош тоткандай кайтты, бүлмәгә атылып та керде, дәреслекләрен барлап, имтиханнарга әзерләнергә дә тотынды, шуңа күрә Әхмәтсафа Горький белән очрашуга ялгызы гына китте.

...Ул килгәндә, театр бинасы шыгрым тулган иде. Күбесе яшьләр. Алдагы рәтләрдә таныш йөзләр күзгә ташлана. Әнә Такташ беренче рәттә утыра. Салам чәчләрен әледәнәле бармаклары белән аралап, җай гына артка тарап куя. Кемдер аның каршысына баскан да, тегеңә ниндидер кызык вакыйга сөйләп булса кирәк, авызына караткан. Такташ аратирә як-ягына күз төшерә, йөзе кояштай балкыган, тыенкы гына көлеп тә ала.

Концертны Шамил Усманов әзерләгән. Концерт башланганчы, үзенең кичәгә хуҗа икәнлеген белдергәндәй, пәрдә читен ача төшеп, берничә мәртәбә тамашачыларга күз ташлап алган булды.

Көне буе чабып арыткан иде, кичәсе дә башланып китә алмый. Әхмәтсафа онытылып бетә язган иде, колак төбендә:

— Таптым бит, егеткәй! — дигән яңгыравык тавыш ишетеп, сискәнеп китте. Күтәрелеп караса — каршысында шатлык-сөенечтән битенә алсулык йөгергән көләч һәм сөйкемле Заһидә басып тора.

Әхмәтсафа урыныннан күтәреләә төшеп:

— Заһидә... Син ничек?..

— Һи-и, танымаганга сабышыр микән дигән идем...— Кыз күңелле генә гөрләп алды. Казан аңа килешкән: гәүдәгә тазарып, тулыланып киткән, ә чибәрлеккә килгәндә, күз тимәсен, бүгенге тамашага килгән кызлар арасында аңа тиңләшерлек гүзәлләр булса да, ике-өчтән артмыйдыр.

Әхмәтсафа, берәр танышы күзгә чалынса дип, үз янында бер урын буш тота иде, Заһидә, чакырганны да көтми, шул урынга чумды. Шуннан соң гына чытлыкайланып сораган булды:

— Бу урынны кемгә тота идең, Әхмәтсафа?

— Сиңа инде, кемгә булсын! — Әхмәтсафага күптәнге сыйныфташын очрату күңелле иде, әлбәттә. Шундый чибәр кызның аның янына атылып килеп басуын, теленә бетеп, рәттән урын алуын әнә күпме күзләр күзәтә.

— Хатыңны алдым. Рәхмәт искә төшерүеңә...— диде Әхмәтсафа, кызга иелә төшеп.— Инде онытып бара идем сыйныфташларны. Ара-тирә Саттар килеп чыга — ул да Казанда укый. Тик еш аралашып булмый, ул авыл хуҗалыгы институтында бит. Аны, тәҗрибәле кеше буларак, күбрәк районнарга чыгарып җибәрәләр. Бер командировкадан кайтып керергә өлгерми, икенчесе әзер.

Кыз, серле тавыш белән:

— Сәгыйтов...— дип сүз башлаган иде, аны Әхмәтсафа бүлдерәсе итте.

— Сәгыйтов белән артык борчак пешми, үзең беләсең...

Заһидә, шул сүзләрне генә көтеп торгандай, Фатыйхка ябырылды:

— Фи-и, Сәгыйтовны күргәләгән бар ла аны! Яшьләр клубында әдәби кичә булса, тол чыпчык, килә дә менә сәхнәгә. И тотына яманларга шагыйрьләрне, и пыр туздыра, мин сиңа әйтим. Түз генә. Каян табып бетерә сүзләрен, кем өйрәтә?.. Үзе бер юл шигырь язмаган кеше башкаларны ничек өйрәтә ала, һушым китә инде.

— Такташка да эләгәме соң? — Әхмәтсафа киная белән әйткән сүзеннән көлеп куйды.

— Такташка шул кирәк аңа.— Заһидә алгы рәттә утырган Такташка зәһәр караш ыргытты.— Бар иде яшь чагым, җүләр чагым, шул кеше артыннан Ташкентларга китеп олактым бит, исәркәйгенәм. Җүләрлекләр үтте, акыл утырды, хәзер инде күктән йолдыз чүпләү исәбеннән кайтып, җирдәге асылташларны эзлим.

— Бар микән соң алар? Асылташлар, дим...

— Нишләп булмасын? Менә янымда берсе утыра,— дип, Заһидә аның иңсәсенә кулын тигереп алды.— Авыл килешкән, егеткәй, кара-чутырга әйләнеп килгәнсең. Әллә төнлә дә кояш яктысы сүрелмәде анда? Көндез генә булса, болай ук янмас идең.

— Көндезге кояш та мул сипте нурын, төнге кояшым да бар иде.— Шаяртып җавап кайтарды егет.

— Кызларны акылдан яздырып бетергәнсеңдер инде, чибәр син, Әхмәтсафа!..

Ул арада шаулатып оркестр уйнап җибәрде. Сәхнәгә Максим Горький чыгып, президиум өстәле артыннан урын алды. Озакка сузылган алкышлар. Сүз өзелде, Заһидә егеткә сыеныбрак утырды. Салих Сәйдәшев җитәкчелегендә музыкантлар татар халык көйләреннән тезмә башкарды. Аннан бер-бер артлы артистлар, язучылар сүз алды. Атаклы язучыга сораулар яудырырга да өлгерделәр. Бигрәк тә башы пеләшләнә башлаган берәү каныкты аңа.

— Сез, Рәсәйдә яшәүче халыкларның әдәбият үрнәкләрен туплап, сайланмалар бастыра башлаган идегез. Ни өчен татар әдәбиятын бастырып чыгармадыгыз? — дип сорау бирде ул.

— Булды ул хәл,— дип гөрелдәде Горький, урысларның нижгар сөйләше белән.— Әрмәннәр чыкты, литвалылар... татарларга килсәк... Тәрҗемә әйберләр бит. Сыйфаты начар булды, вакыт үтә торды.

— Ә Гаяз Исхакый әсәрләре?

Горький күптәнге танышын очраткан шикелле яктырып китте.

— Әйе, Гаяз Исхаков белән иҗади хезмәттәшлек иттек без. Берничә әсәрен урысчага тәрҗемә итеп бастырып чыгардык. Үзем булыштым. Әмма ният тормышка ашмады — аның да сайланма әсәрләрен җыентыкка туплап бастырырга иде исәп. Бик тынгысыз егет иде бит, әле төрмә, әле сөрген… Җитешә алмадык. Кайда соң әле ул бөек язучыгыз?

Зал шаулап алды.

— Эмиграциядә,— диде Шамил Усманов, төксе генә.— Советны кабул итә алмады…

— Әйе-е,— дип уфтанды Горький, тирән уйга чумган хәлдә.— Күпләрнең фаҗигасе бу. Совет хөкүмәтенә җиңел түгел. Дошманнар чолганышында яшәүнең ничек икәнен моны үзе кичергән кеше генә белә. Без ил белән кичерәбез. Ил белән килгәнгә түзәрбез, авырлыкларны ерып чыгарбыз. Мин моңа ышанам. Сезгә дә, дусларым, тормышка аек акыл белән карарга кирәк. Һәр өлкәнең, республиканың эчке дошманнары бар, аларны фаш иткәндә, җирле үзенчәлекләрдән оста файдаланырга иде. Алда — көрәш, алда — җиңү!..

Сүзне Кутуйга бирделәр. Ул, ялкынланып, яттан Горькийның «Давыл хәбәрчесе турында җыр»ын татарча укыды. Укый башлаганчы ук, тәрҗемәнең үзенеке булуын әйтеп куйган иде, Горький Кутуйның укуын зур игътибар белән тыңлап утырды, сүзләрне аңламаса да, интонация, йөз мимикасы, кул хәрәкәтләренә карап, әсәргә ияреп, кайсы төше икәнен чамалап барды булса кирәк, Кутуй укып бетергәч, Горький, халыкка кушылып, озаклап, чын күңелдән кул чапты. Аның бармаклары озынча, уч төпләре киң сыман күренде Әхмәтсафага. Янында Заһидә утыруы бу кичәне иркенләп карарга комачаулый иде,— барыбер ул үзен бу хәлдә уңайсыз хис итте. Ара-тирә кыз аның беләкләренә кагылып ала, кызык тоелган җирләрдә ихлас көлә, үзен иркен тота иде. Әхмәтсафаның игътибарын яуларга теләвен яшерми дә иде, ахры. Егет моны сизеп утыра, эчендә ут, әледән-әле Рабиганың моңсу карашын тойган сыман була, мондый хәлгә төшүе бер дә күңелле түгел икән, шуңа күрә көләр чакларда да ул җитдилеген югалтып бетермәде.

Горькийга да, тамашачыларга да Асия Измайлова җырлавы нык тәэсир итте. Якты тавыш, һәр борманы җиренә җиткереп башкаруы ук күңелләрне җәлеп итә иде. Чибәр, гәүдәсенә килешле ятып торган зәңгәрсу күлмәк кигән, сәхнәдә үзен-үзе тотышында аерата затлылык, мәһабәтлек бөркелеп тора. Һәр хәрәкәте төгәл, үлчәнгән, мең кат уйланган кебек. Килмәгән җире юк иде бу җырчының. Башта ул Горь-

кий үзе дә яратып җырлый торган «Кояш чыга да, бата да...» җырын башкарды. Татарча «Тормыш төбендә» әсәреннән Сәгыйть Рәмиев тәрҗемә иткән икән.

Кояш чыга да, бата да...
Төрмәм мәңге караңгы...
Көннәр, төннәр зобанилар, — их!
Тәрәзәмне караулый...

Горький җырны, алга иелә төшеп, бөтен барлыгы белән йотылып тыңлады. Ул да булмады, Асия Измайлова җырны чип-чиста урыс телендә дәвам итте:

Как хотите, стерегите...
Я и так не убегу...
Мне и хочется на волю, — эх!
Цепь порвать я не могу...

Язучы, урысча җыр башлангач, калкынып китте, үзе дә, авыз эченнән генә кушылып, җырлый башлады. Җыр тәмамлангач, баш ия-ия, җырчыны алкышлады. Озын гәүдәсен җил уйнатып, чайкалдырып торган кебек иде ул бу минутта.

Аннан Асия Измайлова халык көйләрен, композитор әсәрләрен җырлады.

Җыр бетеп, алкышлар тынып өлгермәде, сәхнәгә Кави Нәҗми атылып менде, ул, дулкынлана-дулкынлана, Горькийга бер хикәясен бүләк итте.

— Урысчага үзем тәрҗемә иттем, иптәш Горький. «Шобага» исемле. Беренче уңышсыз тәҗрибәләремнән... — дип, үз янына килеп баскан Шамил Усмановка өнәмичәрәк карап, сәхнәдән төшеп китте.

Концерт беткәч, Горькийны яшьләр урап алдылар. Ул исә, беркемгә дә игътибар итмәстән, башта Асия Измайлова янына килде.

— Шамил Усмановның хатыны ул, — диде Заһидә, ниндидер үкенечле тавыш белән. — Пар да килгәннәр инде. Сокланып туймаслык!.. Менә кемнәр бәхетле дөньяда.

...Урамга чыккач, Әхмәтсафа, беләгенә сарылган Заһидәгә ни әйтергә белмичә, шактый изаланып барды.

— Телеңне йоттыңмы, Әхмәтсафа, — дип шаярткан булды Заһидә. Әмма ул нидер сизенә иде, шуклануын үзе дә килештереп бетермәгән шикелле тынып калды.

— Син дә сөйләшмисең бит...

— Мин, Әхмәтсафа, болай гына телчән сыман күренәм. Кирәк чакта бер сүз таба алмый тилмерәм...

— Аңлашылды... Син кайда яшисең, озатып куям үзеңне.

— Иренмәсәң... — диде Заһидә күңелсезләнеп. — Ерак яшәмим, бер әбидә фатирда торам. Син бит минем хакта бөтенләй сорашмадың, — дип, үпкәләгәндәй итте кыз. — Җит-

мәсә, үзеңне сыйныфташ, яшьлек дустым дип йөргән булам тагын...

— Хатыңда барысы да бар иде бит. Котлыйм, техникумны тәмамлагансың, институтка керергә җыенасың. Уңышлар телим.

— Уку дип... Гомер үтә, Әхмәтсафа. Холкым да әйбәт инде үземнең...— Заһидә көлеп куйды. Тик бу көлү ясалма кебек иде.— Төскә-биткә дә ким-хур түгел, тик мин ялгыз... Япа-ялгыз мин шушы шәһәрдә, күз алдыңа китерәсеңме?

— Егетләр очрамадымы юлыңда? Сайланасыңмы дигәндәй.

— Күңелемә ошаганы юк, Әхмәтсафа. Минем җанымны аңлаучы юк. Озата килүчеләр күп, гәп куерта башласаң, үзләренең өч тиенлек проблемалары хакында сүз куертып, баш әйләндерергә тотыналар. Янәшәдә барган кыз ни уйлый, нинди утларда яна, җаны кайда ашкына — уйлап та карамыйлар, җыен кисәү агачы. Үз туксаннары туксан. Тыңлап-тыңлап йөрим дә, куам да җибәрәм үзләрен. Бармы бу дөньяда чын егет?! Шыңшып йөрүчеләрдән туеп беттем инде, гарык!

— Соң алар да ялгызлыктан туеп беткән, үзләрен тыңлаучы табылды дип сөенүче беркатлы татар егетләре ич инде. Бәлки, сабырлык белән тыңлап бетерсәң, сөйләргә сиңа да чират җитәр иде. Аннан егетләргә зарлану, үзләрен кызгандырырга тырышу хас бит. Психологик адым, моны гына аңларлык инде син, артык акыл сатасым килми.

— Алай булдыра алмыйм, Әхмәтсафа,— диде Заһидә, үҗәтләнә төшеп.— Кая хатын-кызны аңларга тырышу? Кая хатын-кызга хөрмәт? Алтыдагы алтмышка. Башта шулай ук икән, яңадан холкы үзгәрер дисеңме аларның? Татарның татарлыгын кислота белән дә бетереп булмаячак. Кызларны кулына төшергәнче, былбыл булып сайрый ул, аннан... Ә хәзер андый сайраучысы да очрамый башлады. Күрәсең, гомер уза, туннар туза...— Заһидә җанланып китте.— Ә син күрдеңме, Шамил Усмановның Асия Измайловага мөнәсәбәтен?! Нинди игътибарлы ул аңа, нинди манера! Искитәрлек. Менә моны аңлыйм мин!

Шактый сүзсез бардылар. Яртылаш җиргә сеңгән йорт янына җиткәч, Заһидә туктап калды.

— Мин кайтып җиттем. Үзгәрмәгәнсең, һаман да шул Әхмәтсафа икәнсең син. Күп сөйләшмисең, хисләреңне җилгә чәчмисең, уйларыңны тотып селкемисең. Серле егет син. Кызлар андыйларга тартыла, беләсең килсә...

— Өч тиенлек сүзем белән ничек инде синең башыңны әйләндерим.— Егетнең сүзләре кинаяле иде.— Минем дә татарлыгым маңгаема язылып куелган, язмыштан узмыш юк.

— Йә инде, төрттереп сөйләшмә! Бөтен хикмәт шунда,

Әхмәтсафа, мин сине сәгатьләр буе тыңларга да әзер. Син миңа ошыйсың. Көлмә, көлмә, төшемә кермәгән төнем юк. Әллә каян, аксыл томаннар арасында адашып йөрисең кебек. Көндезләрен уйлап йөрим. Ни өчен керә микән төшкә, дим. Бер-бер хәл булмадымы, минем ярдәмем кирәк түгелме, дип хәсрәтләнәм. Ахры, түзмәдем, үзем эзләп киттем. Бәхеткә, теге Сәгыйтов очрады.

— Ул сиңа минем турыда бер нәрсә дә әйтмәдеме?

— Ни әйтсен? Аны тыңлап торырга исәбем дә юк иде. Конкрет сорауга конкрет җавап кына кирәк иде. Әллә бер-бер хәл булдымы? — Кыз капканы ачарга җыенган җирдән туктап калды.— Баядан бирле сүзеңнең ата-анасы юк, бәлки, сизенүем дөрестер, ә? Бер-бер хәл булдымы?..

— Әйтә алмыйм, ни дәрәҗәдә дөрестер. Сүзләрең бик серле, әлбәттә, ак томаннарда адашу, дисең бит. Без барыбыз да шундый хәлдә бугай инде. Каядыр барабыз, каядыр ашкынабыз, кая барып чыгасын күз алдына китереп тә бетермибез.

— Илгә, торткан юлыбызга ышанмау дип аңлыйммы, үзүзеңә ышанып бетмәү дипме?

— Икесе дә бар кебек. Мин киләчәккә ышанам, тик нәрсәнедер кирәгенчә эшләмибез бугай. Шуңа эчем поша кайвакытларда, уйламыйча эшләүгә күнегеп барабыз шикелле.

— Әллә ничек сөйлисең син. Бугай... кебек... шикелле... Икеле-микеле сүзләр шунда. Син дә шулай сөйләнгәч инде. Югары белем алырга җыенасың, булачак партия хезмәтчесе!

Әхмәтсафа ачыклык кертәсе итте:

— Шушы укуның хикмәтләре инде. Күп укыган саен, белмәгән нәрсәләрнең тагын да күбрәк икәненә төшенә барасың. Шикләр дә арта... Ә болай, әлбәттә, мин ышанам, илебезнең киләчәге матур булыр, тик без генә булмабыз... Оча алудан мәхрүм булсак та, гомер буе күккә, югарыга омтыла кеше. Җан таләбе — биеклек. Һәр кешедә ике мин яши. Берсе — җирнеке, икенчесе — күкнеке.

— Менә шулай, сөйли белеп сөйләгән кешене тыңлап туймыйм мин. Каян табасың сүзләрен? «Без генә булмабыз» диюең белән генә килешәсе килми. Авызыңнан җил алсын. Яшәргә язсын, яңа тормыш җимешләреннән безгә дә авыз итәргә насыйп булсын.— Заһидә егетнең беләген эләктереп алды.— Шулай да әйт әле, Әхмәтсафа, Сәгыйтов миңа ни дип әйтергә тиеш иде?

— Тиеш дип... Минем кызым бар бит. Вәгъдәләшкән кызым. Рабига исемле. Бер-беребезне яратабыз. Ышаныч дигән идек бит, минем иң нык ышанычым — шул кыз инде.

Турысын әйтәм, Заһидә, син дә акыллы, чибәр кыз. Теләсә кайсы егетнең башын әйләндерерлек. Үз тиңең табылыр, һичшиксез, табылыр. Синең хатны алгач, сөендем мин, күңелдә яшьлек хатирәләре уянды. Яшьлек истәлекләре беркайчан да җуелмый, уңмый икән ул.

— Сине сөендерә алу — үзе бер бәхет инде. Миңа шуңа сөенәсе генә кала,— диде үртәлгәндәй Заһидә.— Иртә уңмаган — кич уңмас, кич уңмаган — һич уңмас. Инде дөньяга ачуым да юк, беркемгә үпкәләмим дә, аңлый гына алмыйм — ни өчен шулай? Шушы якты дөньяда үз тиңемне таба алмый бәргәләнәм бит. Мин теләгән ярлар әллә кайчан парлы булып беткәннәр. Шулкадәрле берәүгә дә кирәкмим микәнни соң мин, ә?

Кыз елый иде...

— Кирәк, Заһидә, бик кирәк син. Әйтәм бит, табарсың син үз парыңны. Сабыр гына ит. Шулай килеп чыкты бит инде, нишләтәсең. Теге чакларда мин сиңа килдем, син миннән качтың. Хәзер мин шундый хәлдә. Язмыш...

— Ярый, Әхмәтсафа, үткән эшкә салават, бүген синең белән очрашу, сөйләшү дә бер юаныч булды күңелгә.— Кыз яшьле күзләрен сөртте. Ул, елаудан туктарга тырышып, сөйләнүен дәвам итте.— Башка вакытларда, очрашкан чакларда диюем, танымыйча да үтеп китмә, ярыймы?! Юкса ачуланырмын...

Заһидә, җавап та көтеп тормастан, җәһәт кенә капканы ачты һәм караңгы ишегалдына кереп юк булды.

...Укулар башлангач, көннәрнең агышы үз эзенә төшкән кебек булды. Әхмәтсафа, җай чыккан саен, Рәбушы янына йөгерә. Ялга каршы Рабига үзе дә Казанга килеп төшә. Мондый көннәр һәр икесе өчен бәйрәмгә әверелә. Көзге кичләрнең берсендә бергәләп Таҗи Гыйззәтнең «Наемщик» драмасын карадылар. Театрны ярату аларга Шираздан йокты, ахры, һич кенә дә яңа премьераларны карамый түзә алмыйлар. Бу спектакль аларны биһуш итте. Хәзер Рәбушы исенә төшсә, үзе дә сизмәстән, Сәйдәш язган җырны авыз эченнән көйләп җибәрә:

Сайрар кошым, сандугачым,
Сайра иртән таң саен.
Мин дә сиңа кушылырмын,
Иркәм, сагынган саен.
Туган илләрдә, сөйгән җирләрдә
Сандугач баласын очырдым һавага.
Син дә оч иреккә, шат яшә дөньяда;
Күтәреп эчегез балларны,
Шат үткәрик алдагы көннәрне.
Күтәрегез чәшкеләрне бал белән,
Үтсен гомерләр сөйгән яр белән!

Көннәр сизелми дә үтә тордылар. Язга чыккач, Бибкәй көйсезләнә башлады:

— Авылны сагынам, кайтам, — дип үкереп елаган көннәре дә күп булды.

Көч-хәл белән укулар беткәнче түздереп, аны Каргалыга озаттылар. «Бу кадәр дә чибәр булса булыр икән кыз бала, бәхеткәйләрең була күрсен, сеңлем», — дип, эчтән теләкләр тели-тели озатты аны Әхмәтсафа. Нигәдер бу минутларда исенә Заһидә төшеп, күңеле сулкылдап куйды. Эзләп-эзләп тә бәхеткә ирешмәсәң, җан өшеткеч бит... Шираз — уку алдынгысы. Ситдыйк Айдаров, Галия Кайбицкая, Зәйни Солтанов, Сара Садыйкова кебек сәхнә йолдызлары аның теленнән дә төшми. Шундый кешеләр белән аралаша алуына сөенеп, бөтен күңелен биреп укый иде ул.

Ә 1929 елның декабрендә, яңа елны каршылаганда, Әхмәтсафа белән Рабига, якын дусларын җыеп, туй мәҗлесе ясадылар. Туйдан соң озак та үтмәде, Әхмәтсафаны Минзәләгә җибәрделәр. Китми чара юк иде, өлкә комитетында ачык әйттеләр: ТКУда алган гыйлемне гамәлдә куллана алучылар гына дипломга ия булачаклар. Башта эш күрсәтегез, аннан белем турында таныклык...

...Әхмәтсафа уйларына шулкадәр бирелгән иде, бүлмә ишеген дөбердәткәнгә сискәнеп китте. Бернәрсә аңыша алмый як-ягына каранып алды. Кая Рабига, кая Бибкәй, Шираз кая? Кая килеп эләкте ул? Нинди өермә китереп ташлады аны монда? Ялгыз һәм кызганыч хәлдә тойды ул үзен. Тышта караңгы төшкән, бүлмәсе дә караңгы... Ул бүген Әмәкәйдән кайтып җитүләрен, Минзәлә төрмәсендәге хәлләрне һәм, өйгә кайтуга, Рабигага хат язарга утыруын исенә төшерде. Менә бит бер генә җөмлә язып өлгергән килеш онытылып киткән икән: «Исәнме, сөеклем Рәбуш...» Күпме вакыт үткән соң болай мәрткә киткән сыман утыруына?..

Тагын ишек дөбердәттеләр, Әхмәтсафа, каударланып, урыныннан торды, барып ишекне ачты. Инде хәтерләми дә ни өчен ишекне эчтән бикләгәндер. Тиз генә хат яза да, йоклап ала, имеш. Йокларсың бар, йомышчы аны канткомга чакыра килгән иде.

— Тиз килеп җитегез, озакламый киңәшмә башлана! — диде дә караңгы өйалдында нәрсәгәдер абына-сөртенә чыгып чапты йомышчы агай. Бу кадәр кая ашыгалар, кая чабалар — аңламассың. Бүген дөнья бетәргә җыенмыйдыр бит. Татлы уйларыннан аерганнары өчен канткомның киңәшмә җыюдан бушамаган түрәләренә чын-чынлап ачуы килеп, Әхмәтсафа киенә башлады.

## V

— Һәр авылга вәкилләр җибәрми торып, күмәк хуҗалыклар төзүне тизләтеп булмаячак,— диде кантком киңәшмәсенә ерак Семиостров волостеннан килгән фирка сәркатибе Фәйзуллин.— ВКП(б)ның волком комитеты тырыша тырышуын да... Хәлдән килгәнчә...

Сәркатип сүзен әйтеп бетерергә өлгермәде, Филиппов кисәк урыныннан күтәрелде һәм ярсыган тавыш белән Фәйзуллинны тынарга мәҗбүр итте:

— Хәлдән килгәнчә?! Тырыша?! Ни дигән сүзләр бу, иптәш Фәйзуллин?.. Волком рәисе Харисов мондамы? — Ул, акайган күзләрен киңәшмәдә утыручыларга төбәп, беркавым тын торды.

Шинель кигән берәү акрын гына урыныннан кузгалды.

— Монда, иптәш Филиппов... Кайда булыйм инде мин...— Харисов дигәннең тавышы бик зәгыйфь иде. Әллә юлдан килеп йончыган, әллә Харисов, чыннан да, үшән кешеме, Әхмәтсафа үзеннән ике генә рәткә алда утырган бу кешегә кызганулы караш ташлады.

— Син нәрсә эчен җыя алмаган бәбкә кебек...— дип җикеренде Филиппов.— Син дә Фәйзуллин кебек, ты-рышы-ып кына йөрисеңме?

Харисов эндәшмәде.

— Әле ул ныгып та җитмәде, иптәш Филиппов, Суыксуда кулаклар белән бәрелештә нык кына эләккәние...— Харисовны үз канаты астына алырга ашыкты Солтанов.

Филиппов өнәми генә кантком рәисенә борылды:

— Әйе, иптәш Солтанов, әгәр дә без шулай «тырышып» кына йөрсәк, безне кулаклар берәм-берәм чүпләп бетерәчәкләр. Урман авызында башы белән карга чумган көртлекләр кебек бит хәлебез. Башны яшереп, к... өстә тырпаеп торгач, билгеле, өшкереп кенә үтәчәк кулак өере өстән. Сабый балалар нидер майтарырга ты-ры-шып азапланалар һәм карткорылар. Алар үз йомышлары белән дә ты-ры-шып кына ишегалдына чыгып керәләр. Ә без — коммунистлар, совет кешеләре, кулда власть, үзебез һаман урыннарда авыл хуҗалыгы артельләре төзүне суза киләбез. Болай барса... Татарстанда иң артта сөйрәлүче канткомга әйләнеп барабыз түгелме соң? Темп кирәк, темп! Мусин,— ул президиумда утыручы оештыру бүлеге башлыгына эндәште,— Семиостров волостена кем бара вәкил булып?

Мусин, кулындагы кәгазьләрне тиз-тиз актарып, шул арада сөйләнеп тә алды:

— Э-э, иптәш Филиппов, ни әле, э-э, бу волостька иң ерак авыллар керүен исәпкә алып, э-э, иптәш Филиппов, яшьрәк,

белемлерәк иптәшне җибәрергә булдык, э-э...— Ул кирәкле кәгазен тапкач, сөенеченнән кычкырып ук җибәрде.— Менә ул, иптәш Филиппов, бар исемлек... Өлкә вәкиле — Дәүләтъяров Әхмәтсафа, канткомнан Такташев Габдулла. Икесе дә бик грамотный, укыган иптәшләр.

— Дәүләтъяровны беләм...— диде төксе генә Филиппов.— Кстати, Әмәкәйдә әйбәт кенә эшләп кайттылар алар Шәмтиев белән. Габитов мондамы?

Габитовның нечкә тавышы ишетелде:

— Килеп җитте-ек, иптәш Филиппов...

— Ничек эшләр Әмәкәйдә? Вәкилләргә тел-теш тидерерлек түгелме?

— Вәкилләр шулхәтле әйбәт эшләделәр, иптәш Филиппов,— диде Габитов. Аның ялагайлануы ачыктан-ачык сизелеп торганга, бу адәмгә Дәүләтъяров чирканып карап алды.— Кулак элементларын төбе-тамыры белән йолкып аттык авылда.

— Шуннан... Аларны җыеп алып киткәч, халыкны бутап йөрүчеләр булмадымы? Дөресен сөйлә, Габитов, утырыштагы иптәшләргә сабак булыр, әле күп авыллар кулакларны җыеп бетерә алмый иза чигә, кулагын җыйсалар, муллалары кала, аларын да аткарып бетерсәләр — гаиләләрен сөрә алмый ты-ры-ша-лар. Сездә ничек булды?

— Шулхәтле әйбәт булды, иптәш Филиппов, оешкан төстә үтте, сөенеп бетә алмыйбыз инде менә,— диде Габитов. Мактана төшеп, өстәп тә җибәрде: — Без инде, иптәш Филиппов, кайберәүләр кебек «тырышып» тормадык, «дошман элементлар» аңнарына да килеп өлгермәделәр.— Ул учын учка шапылдатып сугып куйды.— Кулакларны озаткач, активистлар урамга чыккан кешеләрне өйләренә кадәр нагайка белән яра-яра озаттылар. Хи-хи-хи, кулак хатыннарын өйләренә үк куып кертеп, базларына ябып куючы батыр йөрәкле активистларыбыз да бар безнең. Бүгенгә кадәр һаман базда ятты күбесе. Ие, чыгып карасыннар! Габитов ике сүләшми ул... Бүген кулак, мулла гаиләләрен авылдан сөрү комиссиясе эшен башлады. Беренче, икенче категориядән берәү дә калмады, сөреп чыгардык авылдан.

— Өченче категорияне нишләттегез?

— Ялгышлык чыкмасын дип, иптәш Филиппов, аларын да сөрдек авылдан. Әле без Минзәләгә киткәндә, авыл башында исәнгерәп йөриләрие, бала-чагаларын җитәкләп. Шунда катып үлсәләр дә, авылга кире кайтару юк аларны. Ие, белсеннәр сәвит блачының ни икәнен!

— Дөрес эшлисез, Габитов! — Филиппов утырыштагыларны янә күзе белән сөзеп чыкты.— Менә кемнәрдән үрнәк алырга кирәк. Власть ул балык кебек, каты кулны яра-

та, тота белмәсәң, кулдан шуа да чыгып китә. Шулай бит, иптәш Габитов?

— Шулай булмыймы со-оң, иптәш Филиппов! Бер тоткач, ычкындырмаскае инде аны... Ничек тә халыкны бәхетле тормышка тизрәк чыгарасые да бит...

Әхмәтсафа үз алларында нинди эшләр торуын бераз чамалый иде инде, Габитовның төче тавышы күңелен болгата башлады. Башкаларны көчләп бәхетле итә алуыңа ышану җүләрлекме, әллә наданлыкмы? Икесе бергә бугай. Залда утыручылар арасыннан вәкил булып барачак Такташев фамилияле кешене күзли башлады.

Такташев... Такташ... Күпме күзләп маташса да, ул Габдулла исемле таныш булмаган кешенең кемлеген яисә мондамы-юкмы икәнлеген дә чамалый алмый иде. Киңәшмә күптән башланып, инде төн уртасы үтеп бара, һаман да бер сүз, бер таләп: февраль урталарына авылларны йөз процент колхозлаштырып бетерүне алга сөрә кантком. Филиппов каткат тәкрарлый:

— Без Татреспубликада үрнәк булырга тиеш. Иптәш Разумов бездән шуны көтә дә! Минзәлә канткомында колхозга кермәгән бер генә хуҗалык калмаска тиеш. Аерым хуҗалык калса, салым-налоглар белән тәмам тезләндерергә, ихатасында каккан казык калмасын, өендә идәне белән түшәменә кадәр сүтеп алып бетерергә! Андыйларның юлы шул — йә күмәкләшү, йә сөрген. Партия установкасы шушы.

Ул көнне киңәшмә таң атканда гына таралды, хәер, төнне дисәң, тагын да дөресрәк булыр, Әхмәтсафа күпме эзләнмәсен, Габдулла Такташевны күрә алмады. Мусиннан сорашкан иде, исе дә китмәгән хәлдә:

— Аптырама, Дәүләтъяров, ул әле килеп җитмәде. Мәскәүдә укыган егет,— диде.— Семиостров волостена кергән Суыксу авылында активистлар өчен курслар оештырган идек. Аны шунда җибәрәбез дип йөрү, нишләп тоткарлана торгандыр. Кәгазе килде, үзенең күзгә күренгәне юк. Мәскәү ашыгырга кушса да, үзендә чарланып кайткан кешеләр бер дә кабаланмыйлар әнә. Сиңа әле берәр атна көтәргә туры килер, канткомда кәгазь эшләре күбәеп китте, һич өлгереп булмый,— дип зарланып та алды Мусин.— Киңәшмәдән бушап булмый, ә Казан кәгазь сорый. Аңа кәгазь генә булсын. Иптәш Филиппов әйтмешли, без бумажки — ты букашка, с бумагой — человек! Шундый хәлләр, Дәүләтъяров, монда.

* * *

Суыксуга Әхмәтсафа гыйнвар ахырында, төгәлрәге айның егерме сигезендә чыгып китте. Юлга кузгалыр алдыннан аны Мусин янә үз янына чакырып алды, өлкә вәкиленә

сынаулы караш ташлап, бераз тын торгач, сүзне уратыбрак башлады:

— Семиостров волостеннан кайткач, Харисов белән Фәйзуллиннан сиңа холыкнамә-характеристика сорап алачакбыз. Өлкә комитетының кушуы буенча. Аеруча Комвуздан җибәрелгән вәкилләрнең эшен аерым контрольдә тотарга кушылган. Сәбәбен төшенеп тә җитмим, син ничек уйлыйсың, ни өчен сезгә аерым игътибар, Дәүләтъяров? — дигән булды Мусин, хәйләкәр көлемсерәп.

— Белмим шул... — диде Әхмәтсафа, аптыравын яшермичә.

— Иң куркынычы шунда шул, без сыйнфый сизгерлекне югалта барабыз. Бухаринчыларның партия үзәк комитетына ыргылуларын күргәч кенә, бераз аңга килдек. Анда да иптәш Сталин барысы хакында бәйнә-бәйнә аңлатып биргәч кенә. Хәзер инде сер түгел, Комвуз озак еллар буе бухаринчылар оясы булып килде. Аларның һәр идеясе ТКУда шытып, үсентеләр биреп, чәчәк атты, бәхеткә сәбәп, җимешләре өлгереп җитмәде, ягъни, сезнең кебек шәкертләргә бу чир ныклап йогып, заразасы киң халык массаларына үтеп керергә өлгермәде. Без бүген синең белән суган суы сыгып утырмыйбыз, гаять мөһим нәрсә хакында бара әңгәмә. Миннән калмасын, сиңа киңәш тә, таләп тә: Комвузда колагыңа кереп калган бухаринчыл бер генә идея дә Минзәлә канткомы җирләрендә борын төртеп, шытып чыгарга маташырга тиеш түгел. Ишетсен колагың, Дәүләтъяров, һәр эшең кантком карарларына нигезләнгән булсын, үзбашка эш майтарырга уйласаң, үзеңә үпкәлә. Юлың туп-туры Минзәлә төрмәсенә! Кулакларны инде җыеп бетереп барабыз, ләкин яу тукталмаган, авылларда кулак куштаннары соңгы көрәшкә күтәрелә, алар һаман каршылык күрсәтәләр. Решительный бул, җебеп, йоклап йөрмә, хәлләр катлауланып китсә, шундук канткомга хәбәр сал, монда без кораллы комсомол отрядлары оештыра башладык. Алар ярдәмгә килеп җитәр.

Әхмәтсафа, сез сөйләгәннәр минем өчен яңалык түгел дигәндәй, Мусинның сүзләрен артык әһәмият бирмәгәндәй тыңлады, шулай да җавап кайтармый булдыра алмады:

— Сез юкка кызасыз, иптәш Мусин. Бухарин сөйләгән нәрсәләр әле күптән түгел генә партиянең генераль линиясе иде бит.

— Сукыр тавыкка бар да бодай, Дәүләтъяров. Бухарин Үзәк Комитетның башын белеп әйләндерде, кәнишне. Ул «генераль линия»не яхшы беләбез. Иптәш Сталин илдә социализм нигезен салганда, вакыт һәм көч сарыф итмәү өчен, ул лыгырдыкларга әллә ни игътибар итмәде, ил ныклы адымнар белән алга бара башлагач, түземлеге төкәнде, кәнсә дә

кәнис, аларга да чират җитте. Аң бул, Дәүләтъяров, социализм төзелеше тамырлана барган саен, сыйнфый көрәш тә көчәя. Без бүген кулакларны кырып себерербез себерүен, әмма болары бит аның ачыктан-ачык дошман, күзгә күренеп торганы. Әгәр дә кулаклар бетү белән авылда сыйнфый көрәш бетте, дип йокымсырап йөрибез икән, бигайбә, барып чыгачакбыз. Иң авыры — яшерен дошманнар белән көрәш.

— Алары ниндирәк була? Партизаннар юк бит хәзер.

— Ай-һай, Дәүләтъяров, Комвузда укуыңның поты бер тиен икән. Нәрсәгә генә өйрәттеләр соң сине анда?

— Политэкономия...

— Күренеп тора, җирдән, тормыштан аерылгансыз. Бухаринга сезнең кебек сары томшыклы чәүкә балалары кирәк булган да инде. Яшерен дошман — кешенең аңында яткан, әле тышка бәреп чыкмаган дошманлык ул. Аның тышка бәреп чыгуын көтеп ятсак, ахыры начар булачак. Һәр өч крестьянның икесе шундый чир белән авырый. Безнең бурыч — иң яман чирлеләрен аерып алып дәвалау, барып чыкмаса, ящур эләккән мал кебек юк итү. Әйе, әйе, гөнаһсыз күзләреңне төбәп торма миңа, юк итү! — «Юк итү» сүзенә басым ясап кабатлады Мусин, калын кашларын җыерып.

Әхмәтсафаның аркасына салкын тир бәреп чыкты. Минзәләгә килгәннән бирле бертөрле сүзләр ишетә ул: юк итү, тамырын корытабыз, кыру-себерү, сөргенгә олактыру. Ул авылларда кемнәр калыр да, колхоз дигәненә кем кереп, кем эшләр, бу хакта баш ватып та торучы юк.

— Габдулла Такташев... кем була ул? — Кабатлап сорамый булдыра алмады Әхмәтсафа.

Мусин дустанә көлеп җибәрде:

— Фамилиясе таныш тоеламы?

— Әйе шул. Кемнедер хәтерләтә.

— Һади Такташның энесе ул. Мәскәүдә уку тәмам иткән. Абыйсы кебек үк башлы егет. Безнең бәхеткә шигырьләр язмый икән. — Әхмәтсафаның ничектер сәерсенеп каравын күреп, ачыклык кертергә мәҗбүр булды. — Беләсеңме, Дәүләтъяров, ул шигырь язучыларга ышанып бетмим мин. Әллә ничек, җир кешеләре түгел бит алар. Димәк, шагыйрьмагыйрьләрнең совет иленә кирәге дә шуның хәтле генә. Менә язсыннар иде алар ничек итеп колхоз төзү фронтында Мусин дигән большевикның кан-тир түккәнен. Рәсәйне, кулга кылыч тотып, аркылыга-буйга айкап чыктым мин. Минем хакта язарга тиешме алар? Тиеш! Юк, язмыйлар. Ә болай... Ниемә кирәге бар аларның?

— Сезнең кебек дөнья күргән кешегә ярап бетүләре кыен... Шагыйрьләр халык җанын җырлыйлар бит алар. Ха-

лыкның күңелендә — шагыйрьнең телендә. Аның табигате башка бит, шагыйрь һәр бөредә могҗиза, тылсым күрә...

— Төкерим мин аларның теленә, бөресенә, тылсымына. Такташның шигырьләрен укыган бар — гыйшык-мыйшык, мәхәббәт тәүбәсе, әтәч урлау, тун кайгысы...

Әхмәтсафа, тел чарлап торуның файдасы юк икәнен аңлап, чыгу ягына кузгалды. Суыксу якларын ишетеп кенә белә, таныш түгел авылда аны көтеп торучы бармы, соңга калынса, кайда барып баш төртер!.. Көн үтә тора, ашыгырга кирәк.

— Кстати,— диде Мусин, Филипповча итеп,— Такташевны мин Казанда үзем таптым. Аны Мәскәүдән Казанга, наркомпроска юллама белән җибәргәннәр иде. Мин дә кадрлар мәсьәләсендә анда сугылып чыгарга булдым. Кабул итү бүлмәсендә танышып киттек, сөйләшә торгач, тәки ризалаштырдым моны Минзәләгә килергә. Уен түгел, Мәскәү университетын тәмам иткән кешеләр минут саен юлда очрап тормыйлар. Шулай, иптәш Дәүләтъяров, кадрларны бөртекләп җыябыз. Тик менә...— Мусин, әйтим микән, юкмы дигәндәй, беркавым сүзсез торды, кулын кулга сугып, әйтеп салды,— ул үзе дә кулак нәселеннән бугай. Үзенең килеп күренгәне юк, язу килде өстеннән. Кулак малаена мондый җаваплы эшне тапшырып булмас кебек. Суыксуга җибәрүне әйтәм. Кадрлар җитмәгәч, исемлеккә керткән идем инде. Көтмә син аны, иң яхшысы шул булыр... Күрәсеңме, аз гына сәяси уяулык җитмәү, нинди хаталар китереп чыгара.

— Такташ ничек кулак булсын? — дип, ишек катында тукталды Әхмәтсафа.— Егерменче елларда, ачлыктан качып, Оренбур якларына килеп, каңгырап йөрде ул. Кулак булса, рәхәтләнеп өендә ятар иде.

— Күп сүз бозау имезә, кулак түгел икән, бик әйбәт. Әмма шундый сигнал булды. Без сыйнфый миңгерәүлек күрсәтергә тиеш түгел. Егетне Суыксуга җибәрмәячәкбез, мәктәптә укытсын әнә.

...Мусин, сүзен беткәнгә санап, Әхмәтсафага кулын сузды.

— Әйдә, күрсәт егетлек. Нинди генә хәлләр булса да, без сине ташламабыз!

Ул каударланмый гына урамга чыгып китте. Салмак кына кар ява иде, кисәк җил күтәрелеп, ул кар өермәсе уртасында калды. Бөтен өсте кар гына, хәтта куенга кар тулып, тәнен өтеп алды. Ә күңелдә, теге чорның кадерле истәлеге булып, Такташның соңгы сүзләре ишетелә: «Читләшмә бездән!»

Читләшмәссең... Хәсрәтле көлемсерәп куйды Әхмәтсафа. Ничек кенә читләштерә дөнья. Әле кайчан гына Казан урамында йөри иде, хәзер менә Минзәләдә күз күрмәгән, колак ишетмәгән хәлләр эчендә кайный.

...Суыксуда активистларга «Күмәк хуҗалык итүнең икътисадый нигезләре» хакында дәресләр бирә башлагач, «читләшү» дигән сүзнең асылына янә бер мәртәбә төшенде Әхмәтсафа. Белем бер нәрсә, гамәл икенче нәрсә икән. Айхенвальд түгәрәгендә алган белемнәрне монда кулланып булмый, аларга партия Үзәк Комитеты «дошман казынулары» дип бәя бирде, бер чара кала, ул Казаннан ук алып килгән газеталардан Үзәк Комитет һәм өлкә комитеты чыгарган карарларның асылын аңлаткан булып көннәр үткәрде. Фирка карарлары каршылыклы, күп тезисларын шәрехли башласаң, аларда акылга муафыйк бер нәрсә юк икәнлеге җүләр кешегә дә аңлашыладыр кебек.

Шул рәвешле Әхмәтсафа Дәүләтъяров, партия таләбе буенча, крестьяннарны ирексезләп колхозларга куып кертү тарафдары булып китте. Бер төрле уйлап, икенче төрле эшләүнең ачык мисалы иде болай гамәл кылу. Әмма ВКП(б) Үзәк Комитеты карарларына каршы килүне ул башына да китерми, кантком киңәшмәсендә кабул ителгән «Йөз процент күмәкләштерү» шигарен тормышка ашыруны үзенең намус эше дип карый, аның үтәлүе өчен көн-төн йокламаска да әзер иде. Кызык бит адәм баласы, беренче карашка ук көлке тоелган идеяләрне туктаусыз кабатлый торгач, Әхмәтсафа аларга тәмам ышана, алар белән агуланып, чынны ялганнан аера алмый башлады.

Ул көннәрдә йокы аз эләкте аңа...

* * *

Әйе, үзәкләргә үтә икән ул йокысызлык... Дәресләр, аннан волком йомышлары белән йөгерү, бетмәс-төкәнмәс киңәшмә, җыелышлар... Өлкә комитет вәкиле буларак ул берсеннән дә калырга тиеш түгел, һәркайсында чыгыш ясарга кирәк, канткомга тиешле информация биреп бару да аның өстендә.

Менә бүген дә дәресләр тәмамланып, урамга чыгуга, шундый арыганын тойды ул. Суыксу урамында этле җан да юк. Ул авыр адымнар белән фатирга таба атлады. Көн төшкә авышып килә. Авыл буйлап үткәндә, күптән түгел генә нардомга әйләндерелгән мәчеткә күзе төшеп, йөрәге кымырҗып куйды. Элекке елларда бу вакытта мәчет тирәсендә илаһи җанлылык сизелер иде: инде өйлә намазына азан әйтелгән, мәчет картлары намазга гына йөри торган кыска кунычлы каталарын аякларына элеп, урам уртасыннан вәкарь кыяфәттә, әмма аерым бер ашкыну белән мәчет ягына юл алырлар иде. Хәзер мәчет, үзгәртеп корылып, нардом, ягъни халык йорты дип атала. Яшьләр, барысы да түгел, әлбәттә, үз-

ләрен комсомол дип атаучы сугышчан, аяусыз төркем мәчет бинасында һәр көн диярлек кичәләр үткәрәләр, китапханә оештырып җибәргәннәр. Әнә китапханәче егет үзе дә мәчеттән килеп чыкты. Төшке ашка кайтып килергә чамалый торгандыр инде, муенын бишмәт якасы эченә җыерып яшергән, шикләнеп, як-ягына каранды һәм ишекне бикләргә җыена башлады. Килүенә, йозагына кемдер тизәк сылап куячак. Егет берничә мәртәбә бу хакта кантком вәкиленә жалу белән килде, саклап та торган булдылар, әмма, көндез булмаса, төнлә, кич яшьләр таралгач, йозакка мул гына итеп шушы «нигъмәтне» сылап китәләр иде. Суыкта шакырдап каткан нәмәрсә белән беркемнең дә мәшәләнәсе килми, комсомол ячейкасы секретаре сукрана-сукрана үзе ачып биргән йозакны өченчекөн. Китапханә мөдире: «Бу хәшәб эш тукталмаса, яңадан мәчет ягына борылып та карамыйм»,— дип, ясканган булды да бит. Кая барсын, авылның иң хәерче кешеләреннән берсе ул, ни җире юк, үзенең йорты исә, бүген аумасам, иртәгә чамалый башлармын, ахры, дип кенә тора. Егет телгә-сүзгә шәп булса да, кулыннан әнә шул йозак белән булышудан башка бер дә эш килер сыман түгел. Ә үзе башлы күренә, яренгә Казанга укырга китәм, белем алам, хөкүмәт кешесе булам, дип адарынып йөри. Үз хуҗалыгында тәртип урнаштыра алмаган, үз йортының түбәсен кирәгенчә ябып куярга хәленнән килмәгән кешедән нинди хөкүмәт кешесе чыгар, бер Алла белә...

Арыткан иде. Фатирга кайтып керүгә, ашык-пошык чишенде дә урын өстенә тәгәрәде. Ул кантком тарафыннан иң зур волостьларның берсе булган, җирле халык атап йөрткәнчә, Семиастрауга вәкил итеп билгеләнде. Авылның татарча исеме — Өшәр. Суыксуда ачылган курсларда сабак бирүне авылларга чыгу белән алыштырып алып барырга туры килә. Волостьта утыз биш авыл бар. Һәркайсында булырга, хәлне контрольдә тотарга туры килә.

— Кара як,— диде бу төбәк хакында Мусин, аны озатканда.— Эш ягыннан әйтмим, тырыш, дөнья көтүнең рәтен белгән мул тормышлы халык яши иде монда элгәре. Совет чорында күбесенең көймәсе комга терәлде.— Мусин, масайган рәвештә, күкрәген алга чыгарды.— Күрсәттек без аларга ничек мул тормышта яшәргә икәнен. Ояларын туздырдык! Хи-хи... Менә шуңа да караңгы як дип атыйбыз хәзер ул якны. Советка бик тә каршы төбәк ул. Гомер-гомергә үз кануннары белән яшәгән халык. Бүрек ыргытып кына җиңешле түгел. Ошатмасалар, дин әһелләрен дә куып кына җибәрә торган як. Шуңа күрә дини яктан бик көчле, укымышлы һәм бернәрсә алдында да җебеп-калтырап төшми торган хәзрәт-муллалар җыелган иде бу тирәгә.

— Табигый сайланыш...— диде көлемсерәп Әхмәтсафа. Бу сүзне еш һәм яратып куллана иде ул.

Мусин ялт аңа карап алды. Йөзе җитдиләнде, суырылып калды. Инде ничә мәртәбә искәртте, әйбәт кенә сөйләшеп торган җирдән Казан студенты, кинәт кенә ул бик үк аңлап бетмәгән телгә күчеп, гәп куерта башлый. Үзенең белемле, зиһенле булуын күрсәтергә тырышамы?.. Бу хәл аның ачуын китерә иде.

— Нинди нәмәрсә ул «сайланыш» дигәнең?

— Тимирязев дигән академикның хезмәтләрендә укыдым мин аны. Дарвин дигән инглиз галиме булган. Ул җир йөзендәге һәр җан иясе шушы табигый сайланыш нәтиҗәсендә эволюция, ягъни үсеш-үзгәреш кичерә дигән. Шартларга яраклаша алган җан иясе исән кала, яраклаша алмаса — һәлак була. Көчлеләр генә яшәргә хокуклы. Хәзрәтләр дә шулай яшәп, тернәкләнеп калганнар, димәк, биредә.

— Хәзер ул якларда хәзрәтләр калмады дисәң дә була,— диде эчке горурлык белән Мусин.— Җыеп бетереп барабыз. Шулай да Суыксуда сак бул, анда усал, явыз халык яши. Гомер-гомергә җыен сугыш чукмары, алаканатзимагурлар ягы.

Әхмәтсафа монда килгәч шуңа төшенде: Суыксуга карата әйтелгән сүзләрне һәр авылга төбәп әйтергә булыр иде. Ниндидер үҗәт, үчлекле кешеләр. Бер-берсен сатарга да күп сорамыйлар. Сәбәбе хакында сораша башласаң, әллә кайчангы хәлләрне искә төшерәләр. «Ярый әле бу якларда тау халыкларындагы кебек кан үче булмаган, күрсәтерләр иде алар бер-берсенә хикмәтләрне!» — дип көрсенеп уйланган чаклары да булгалады. Ә менә берәрсенә авырлык килсә, мир белән җыелышып, хәзер күтәрелеп чыгарга әзер булулары тагын да гаҗәп иде. Аерым-аерым бер-берсен өнәмиләр, хәтта күрә дә алмыйлар, шул ук вакытта сәер оешканлык белән аерылып торалар.

Әхмәтсафа, болай озаклап аунап ята алмасын аңлап, тизтиз генә капкалап алды да, җаны тынгысызланып, көндәлегенә үрелде. Соңгы елларда көндәлек язып барырга һәвәсләнгән иде ул, тик Рәбуш белән өйләнешкәннән соң, көндәлек язуга игътибары кимегән иде. Минзәләдә колхозлар оештырып йөргән көннәрнең ядкаре булыр дип, кичә Чалманарат авылында күргән-кичергәннәрне кыскача гына теркәп куярга булды.

«Егерме бишенче февраль, утызынчы ел...»— дип язды да уйга калды. Күз алдыннан алдагы көннең вакыйгалары йөгерешеп үтте.

Иртәнге җидедә Чалманаратка кузгалды алар. Авыл советы рәисе ат белән олаучы җибәргән иде. Үткер егет, комсо-

молец икән. Юл буе теләсә нәрсә такылдап барып, авылга ничек килеп җитүен дә абайламый калды.

Совет йортына барып керү белән, активны җыеп алдылар. Тугызлап кеше. Колхоз төзү хакында һәркайсының үз карашы, үз тәкъдиме. Бер агай, мескен бүреген әвәләп, урынында таптана-таптана үзенекен тукый.

— Ибдәш кем, вәкилетдин, теге ни әле, аты коргыры, ие, шул инде, күмхуҗга каршы түгел бед,— ди ул, күзләрен нигәдер идәнгә төбәп.— Түлкем дә манау бөтенебед бер җурган астына кереп җоклау дигәненә катыннарны бер дә ырыйдалаштырып булыр кебек сыман тоелмый, ие, вәкилетдин ибдәш. Мин кичәгенәк тә шуның өчен күмхуҗга каршы төштем. Ушы сораугa дөрес җавап ишетмәенчә, хәл кылып булмас кебек сыман тоела. Иеме, ибдәш вәкилетдин.

— Ибрай агай, сиңа сүләргә куш инде,— дип, авыл советы рәисе йөзен чытып куйды.— Каян алдың шул бер җурган асты дигән сүдне. Тукыйм, тукыйм, һич башыңа кермәсә керми икән.

— Син, ибдәш рәис, әтәчләнмә алай, вәкилетдин ибдәш китәр дә барыр ул. Аңа ике дөнҗа бер морҗа, сала саен бер марҗа дигәндәй, сиңа беднең белән каласы...— диде Ибрай, саллы йодрыгын тун кесәсеннән чыгарып.— Синең тукыган синең тукыган ул, синдәге грамота гына беднең үдебеддә дә бар ул, бигрәк кыдыл булып бетәсең кайвакытларда, менә ибдәш вәкилетдин әйтеп карасын. Ул сүләгән рас кебек сыман тоела бедгә.

Әхмәтсафа, аңламаган кыяфәттә, рәискә караш салды.

— Нинди уртак юрган? Бу хакта сөйләшүләр булмадымыни соң? — диде ул, ачулана төшеп.— Һаман төсе уңып беткән җыр җырлап маташалар икән Чалманаратта, дип кайтып әйтсәм, тавыклар көләчәк Минзәләдә. Бу ялганнар мең мәртәбә фаш ителде бит инде. Кулак җыры. Кулак коткысы!

Рәис, башын боргалап, гөнаһсыз тавыш белән сүзгә кереште.

— Әйтмәгән кая да, аңлатмаган кая, иптәш Дәүләтъяров. Кеше башын әйләндерергә туган инде ул Ибрай агай. Аңлаттым — бернинди юрган асты да, юрган өсте дә юк, дидем. Өйгә, өй җиһазларына тимибез, комиссия төзеп, һәркемнең мал-мөлкәтен исәпкә алабыз, аннан соң хәл кылырбыз, дидем. Ашыкмый, кабаланмый...

— Киресен сүлисең, ибдәш рәис,— дип, аңа каршы төште Ибрай абзый.— Кичә әйттең, тид тотарга, вулычта күмхуҗны беренче итеп төдеп бетерәбед, дидең. Хәдер ни сүлисең? Аннан шуны төшендереп бир әле, ибдәш вәкилетдин, менә беднең рәис әйтә: төдибед дә бетерәбед, ди. Тыңлап кына

тор әле син, иеме. Уйлап-уйлап куям да, бер дә хут алып китәр төсле күренми кебек сымак тоела күмхуҗ дигәннәре. Төдибед дә, бетерәбед дә дип яскангач ни... Бу мәләкәдән ни генә калыр соң, шымытыр башымы? Шуңа аптыраш...

Җыелган халык көлешеп алды.

Әхмәтсафа, һаман сабырлыгын җуймыйча, башында баядан бирле бөтерелгән уйларын әйтергә булды:

— Үзегез актив дип аталасыз, үзегезниләр генә сөйләмисез? Мондый актив белән, белмим, колхоз төзеп булыр микән?

Рәис йодрык белән өстәлгә китереп сукты.

— Була, иптәш Дәүләтъяров! Авылда бер контрны калдырмаячакбыз. И без аны калдырмадык дисәң дә ярый, җыеп бетереп барабыз. Алга табан да шулай булачак: кем күмәк хуҗалык төзүгә каршы, авылдан сөреләчәк. Ибрайның сүзенә карамагыз, ул гражданнар сугышы партизаны, авылда беренче совет төзегән кеше, колхоз турында сүз кузгалгач кына сөртенә менә. Хәлле, таза хуҗалык алып бара, үз малыннан колак кагасы килми, шунысы җәл аңа.

Ибрай, ниһаять, җитди сөйләшә башлады.

— Шул шул, ибдәш вәкилетдин, совет өчен кан койганда бед кирәк булдык. Карап-карап торам да, күмхуҗга бед артык. Беднең мөлкәт кирәк, үдебед кирәкмәй булып чыга. Сүдебедгә колак салучы да юктыр кебек сымак тоела. Әүвәл өйгә кереп, баш астына салып яткан мендәрләрне, кетәклектәге тавыкларга кадәр санап чыктылар, халык шикләнә башлады. Төрле сүд китте, чыш-пыш. Бед, совет членнары, аңлата алмайбыд, чөнки үдебедгә җүнле-башлы аңлатучы юк. Рәис ибдәш дөрес әйтте, авылда укымышлы кешеләр бар иде, җыеп алып китеп бетерделәр. Хәзер җыен әтрәк-әләм, ура кычкырып йөрергә үрәнгән кешеләр генә калды авылда. Укымышлы кеше бетсә авылда, иң белдекле кеше хатын-кыд булып кала икән ул. Беднең хатыннар көн-төн җылайлар, бер җурган астына җаткырып, адәм мәсхәрәсенә әйләндермәкчеләр икән дип дулайлар. Бед монда утырабыз, хатыннар абыстай янында «белем» арттыралар, гайбәт таралар, сүд җөртәләр, итәк астыннан ут җөгертәләр. Менә бит ул ничек.

Әхмәтсафа активка күмәкләштерү хакында тулы бер дәрес биргәч, авыл буйлап һәр хуҗалыкның малын, мөлкәтен барлап чыктылар. Шунда күрде инде ул кешеләрнең берберсенә сәер мөнәсәбәтен.

Бер кешеләрнең малларын язган чакта, бер адәм шыпырт кына килеп:

— Ибдәш вәкил, җукка мескенләнә бу Шәрип дигән кеше, аның би-ик шәп биясе бар, күрше авылындагы киявендә тота. Тегенең үткән көд аты үлде, бу шуңа шылдырды атын.

Кем әйтте дисәләр, үдем белдем диген, биясен өстәп җадып куй, алып кайтсын Шәриптән биясен, күмхуҗга тапшырсын!

Ибрайның мөлкәтен исәпкә алганда, икенче бер активист чыш-пыш килде:

— Һи-и, аның трантасыннан җилләр искән икән бит, ишегалдында гына тота иде. Бер дигән трантасын җәшергән, шельма. Кормаштагы кызына илтеп куйгандыр инде. Тагын кашка тае күренми. Төртеп куй, иптәш вәкил. Бар ул аның, бар, яшереп маташа, мыкыр. Таптырырга кирәк барысын да!..

Советка кайтып, һәр хуҗалыктан ни-нәрсәне күмәкләштерү мәсьәләсен хәл иткәндә, Әхмәтсафа исемлектән шундый «яшерелгән» милекне дә әйтеп бара башлагач, башта шаулашып алганнар иде, аннан тындылар, аңлап алдылар булса кирәк, монда кемнең кемне сатканын тикшереп утырасы юк, бу «барлауга» һәркем үзенең өлешен керткән иде.

Ибрай гына, ачу белән:

— Ил күденнән җәшерен эш булмас, барысын да теркәгән икән, каһәр,— дип куйды.

Аңа каршы дәшүче булмады, бер-берсенең күзенә күтәрелеп карарга да кыймый иделәр бугай. Милек барлау караңгы төшеп, кичке сәгать җиделәрдә генә бетте.

Актив утырышы кичке унынчы яртыга кадәр сузылды. Капкалап алырга өлгермәделәр, тагын халык җыйнала башлады. Көн тәртибендә —ярлылар җыелышын үткәрү каралган иде.

Әхмәтсафа, һәркемгә аңлаешлы булсынга тырышып, авылда күмәк хуҗалык төзү тәртибе хакында аңлатырга кереште.

Әмма аны шунда ук бүлдерделәр:

— Апай, энекәш, бедгә бу хакта суган суы сатма син. Үдең, үд күдләрең белән берәр күмхуҗаны күргәнең бармы? Ни майтаралар алар анда? — дигәнрәк сораулар яудырырга керештеләр.

— Күргәнем бар,— диде Әхмәтсафа, тавышланучыларны тәртипкә чакыргандай, кулын өскә күтәрә төшеп.— Мин үзем Оренбур ягыннан, Татар Каргалысы дигән авылдан...

— Җәһәннәмнән икән...— диде кемдер.— Соң, апай, седдә дала, күмхуҗ булса ни, аерым булсагыд ни, ике чабата бер кием, җаңгыр бирсә Ходай — иген уңа, ад гына корырак булса — басуыгыд көеп бетә. Гомерегед ач даланы җырмачлап үтә инде шунда. Беднең туфраккайларны белсәң син, апай. Тәгәрмәч күмсәң, трантас үсеп чыга бит. Шушы алтынга биргесед җиркәйне теләсә нинди әтрәк-әләмгә ышанып тапшыр инде?! Белер-белмәс җиргә тотынсаң, җирнең хәдер көе югала бит аның, апай. Уйлап караганың бармы, бу

җиркәйләрдән ни калыр, әгәр дә ки теләсә кем кулына җир тапшыра башласаң?

— Аптырама, Шәрип абзый,— дип бүлдерде аны рәис,— сине җир өчен җаваплы итеп куярбыз. Агротехник дип атала ул вазифа йөкләнгән кеше.

— Анысын куярсыд куюын,— диде абзый, һаман бирешәсе килми.— Вадыйфасы булса, кешесен табарсыд аның. Бер эт җалкавы җирне мыскыл итеп, бәрәкәтен җибәреп җөрсен, аның өчен мин җавап бирергәме? Җук инде, бигайбә. Аннан мин күмхуҗга ике ат, шыңгырдап торган бүрәнәдән өч келәт бирәм ди. Шулай җадып куйгансыд, әнәтерәк. Минем күрше — җаңгыд баштан дөнҗа көтүче Бакый корткасы да күмәкләшеп җөрмәкче. Ихатасында бер шырпы салам кисәге җук, эскәк белән эдләсәң дә табам димә. Минем өйдә айгыр хәтле ике җегет, пләмәннәй үгед урынына җөк тарта алар, кирәк булса. Бакый корткасының тилебәрән ашаган малаеннан ни көтмәк кирәк?

Халык көлешә, шаулаша башлаган иде, алгы рәттә утырган хатын, сикереп торып, чәр-чәр килә башлады:

— Мыскыл итмә, Шәрип тәресе, туйдым шул мыскылларыңнан, илаһым. Минем Бакыем шушы совет өчен башын салды, улым Рәхмәтуллам җәтим-җилпе үсмәсә, синең айгырларыңнан кәм булмасые, әле дә, Аллага шөкер, үд көчебед белән көн күрдек. Курыкмыйм, теләсә ни әйт, мин күмәк хуҗалыкка керәм. Күрербед, бергә-бергә эшли башлагач, кемнең айгыр, кемнең алаша икәнен...

Халык тагын гөр килде, тагын әйткәләшү, әрепләшү китте. Авылдагы ярлыларны барлап, аларның бер-берсен сүз-тел белән рәнҗетүләрен тыңлап утыра торгач, төнге унике җитте.

Көне буе чабып арыган рәиснең башы әледән-әле бер якка кәнкәеп ала. Ләкин әле эш тәмамланмаган. Ярлылар җыелышы тәмамланугa, гомуми җыелыш башлануы хәбәр ителде. Килгән һәр кеше совет йортына кереп тула торганга, инде тын алу кыенлаша иде, ишекне ачып, бүлмәне җилләтеп алырга булдылар. Сулыш алу иркенәйде, баш бераз җиңеләйде кебек. Әмма бу озакка бармады, халык:

— Суык керә, ябыгыз ишекне, катырып үтерергә җыйдыгызмы безне?! — дип шаулаша башлады.

Җыелыш әрепләшү-аңлату рәвешендә иртәнге өчкә кадәр барды. Ник бер кеше: «Җитәр, булды!» — дип сөрән салсын да, ник бер кеше кайтыр якка кузгалсын. Тәмам арып беткәч, ниһаять, уртак фикергә килеп, күмәк хуҗалык төзергә дигән карар чыгарылды. Халык көне буе, төне буе үз-үзе, гаиләсе белән дә, күрше-күлән, таныш-белеш белән дә киеренке бәхәстә, тартышта иде, шуңа күрә күзләрдән йокы кач-

кан. Авыл тормышында, һәркайсы язмышында иң мөһим мәсьәлә — җирне, милекне күмәкләштерү мәсьәләсе хәл ителгәндә ничек күзеңә йокы керсен дә, ничек бәхәсләшмисең? Йокысызлыктан исәңгерәгән кебек күренсәләр дә, монда һәркем уяу, һәркем зиһенен тулы куәткә эшләтә иде...

...Менә хәзер Әхмәтсафа Дәүләтъяров шушы көннәрнең кайнар сулышын көндәлегенә теркәп куймакчы булып утыра. Бу вакыйгалар хакында еллар үткәч кем дә булса кызыксынырмы, әллә искә дә алмасмы, анысы киләчәк эше. Әхмәтсафа тәне кызышуын тойды. Йокысыз төннәр, туктаусыз авылларда йөрү сәламәтлеген какшата, җегәр кими иде. Вакыт бар чагында, тагын кемдер килеп, кайдадыр алып киткәнче, ял итеп алырга кирәк. Тиз-тиз генә көндәлегенә көн вакыйгаларын чагылдырган түбәндәге сүзләрне сызгалап куйды: «Бишенче февраль, 1930 ел. Иртәгә җиде сәгатькә Чалманаратка. Иртән актив белән сөйләшү. Иртән тугыздан кич җидегә кадәр опись. Җиде сәгать ярымнан тугыз сәгать ярымга кадәр актив җыелышы. Төнге уникедән иртәнге өчкә кадәр гомуми җыелыш.

Ник бер кеше китсен. Бары да кадаклаган кебекябышып ята».

Шушы сүзләрне язып куйгач, Әхмәтсафа урынына барып ауды һәм саташулы йокыга талды. Үзен һаман Чалманаратта хис итә ул. Күз алдында әле Ибрайның чиләк кадәр авыр йодрыгы чагылып китә, Шәрипнең ачулы йөзе шәйләнә, Бакый хатынының чәр-чәр тавышы колакта яңгырап, баш миләрен кадак белән тишкәләгәндәй итә. Гәүдә әле һавага күтәрелә, әле бәргәләнә-бәргәләнә упкынга оча. Шушы сирәк эләккән йокыда килеш тә Әхмәтсафаның аңы күмәк хуҗалык «төзү» белән мәшгуль иде...

* * *

Эшләр көйле генә киткән кебек иде. Авыл кешеләре туктаусыз басым астында күмәк хуҗалыкларга кереп беттеләр. Җиң сызганып язгы чәчүгә хәзерлек башлап җибәрделәр. Беренче эш һәм иң әһәмиятлесе дә шул — колхоз фондын булдыру зарур иде. Гомуми амбарга чәчүлек орлык, фураж салына башлады, хуҗалыклар, күп үгетләрдән соң, сабан-сукасын, тырма ише кирәк-яракларын пай взносы тәртибендә колхозга тапшырдылар. Колхоз милке күзгә күренеп арта иде. Колхоз терлеге дә ишәйде. Атлар мәҗбүри колхозга бирелде, колхозчы кулында бер генә ат та калмады, һәр хуҗалыкта бер генә сыер калдырылды, умарталар тулысы белән колхоз милкенә күчте. Хуҗалыклардагы амбар, келәт-сарай ише корылмаларны сүтеп, колхоз дворына китереп өю

башланды. Кыскасы, Әхмәтсафа түккән тирнең әрәмгә китмәвенә сөенеп йөри иде бу көннәрдә. Әмма көйле эшнең көе китте. Сәбәпчесе... Сталин, тагын да дөресләп әйткәндә, аның исеменнән чыккан мәкалә иде.

«Правда» газетасының икенче март саны әле Әхмәтсафаның кулына килеп эләккәнче үк Сталинның «Уңышлардан баш әйләнү» мәкаләсе хакында авыллар гөж килә башлады. Мәкаләне Фәйзуллин белән икәүләп, аның бүлмәсендә бикләнеп укып чыктылар. Башлар шаулый, күз алдында утлар биеште. Сталин, колхозлаштырудагы бөгелешләрне күрсәтеп, бөтен гаепне урындагы җитәкчеләр өстенә аударып куйган иде. Һәр башбаштаклык өчен урындагы партия-совет җитәкчеләре җаваплы! Акка кара белән язып куелган, бу сүзләр авылдагы һәр кешегә билгеле инде, авыл умарта күче сыман гөжли. Урамнан тыныч кына үтеп китешле түгел, ир-ат халкы юлдан үтәргә бирми, мәкаләдә язылганнарны үзләре аңларга теләгәнчә төшендерүне таләп итеп, янаулар башланды. Киеренке хәлдән чыгу юллары хакында уйларга кирәк иде.

— Әллә ничек булып китте,— диде Фәйзуллин, такыр итеп кырдырган башын кашып.— Кыш буе без иптәш Сталинның: «Колхозлаштыруда темпны киметмәскә, күмәкләштерүне утызынчы елның көзенә төгәлләргә!» — дигән генераль күрсәтмәсен үтәү өчен тире ерттык түгелме соң? Күмәкләштерүдә социалистик ярыш тәртибен кем хуплады, йөкләмәләрне кем раслады, рапортны без кемгә юлладык? Боларның башында Үзәк Комитет тормадымыни?!

— Кызма әле, иптәш Фәйзуллин,— дип, аны бүлдерде Әхмәтсафа.— Һәрхәлдә, без Үзәк Комитет директиваларын да, өлкә комитет күрсәтмәләрен дә бозмадык. Аларны мин биш бармагым кебек яхшы беләм. Төн уртасында уятып сорасалар да...

— Болай булса, төн уртасына барып җитмәвебез дә бар.— Фәйзуллин, йөзен чытып, читкә борылды.— Авылларда ни барганын бер Ходай үзе белә. Иртәгә үк колхозлар таралачак, әнә, кая барма, каршыга килеп җырлап торган булалар: колхуд тары ала микән, колхуд кад ала микән, дип. Җыен тиле-миле көлә бездән. Канткомнан да бер хәбәр юк, телен тешләде Филиппов. Теге чакта барысы да батыр, барысы да гаярь иде. Хәзер су каптылар, авызларына печ итим.

— Ашыгып нәтиҗә чыгару хата булыр иде. Без әле газетаның шушы санында ук басылган крестьян хуҗалыкларының Үрнәк Уставын яхшылап өйрәнмәдек. Бераз күз салып чыгуга ук аңларга була, Үзәк Комитет крестьянның мөмкинлеген, холык-халәтен истә тотарга тырыша. Өлкә комитет,

кантком шуларны өйрәнеп, акыл аша үткәрергә омтыла. Ашыгып эш итүнең җимешләрен татыдык инде. Күп өлкәләрдә крестьяннар чуалышлары булып үтте әнә. Хәтәр хәлләр булуы хакында төрле хәбәрләр ишетелә.

— Бездә дә озак йөрмәс, халык бик кыҗрый. Сыер дуласа, аттан яман, ди. Сиңа рәхәт, син җүләр дигәндәй, син бит, иптәш Дәүләтъяров, вакытлы кеше монда. Казаныңа китәрсең дә барырсың, ә безгә бу кызган таба өстендә нишләргә кала?

— Беренчедән, кемнең кайчан, кайда китүе фирка кулында. Икебез дә фирка әгъзасы. Икенчедән, паникага бирелмик. Әгәр без дә шулай сөйлибез икән, башкаларга нишләргә кала? Әйткәнемчә, без мәкаләне яхшылап өйрәнмәдек әле, өстән фикер йөртәбез. Иптәш Сталин темпка бәйләнми, аны хуплавын белдерә. Егерменче февральгә илле процент коллективлаштыруны уңай яктан бәяли. Уңышларны ныгытырга чакыра. Бу ни дигән сүз? Димәк, безнең хезмәт бушка китмәгән. Таныргa кирәк, кайбер бөгелешләр булды, тизрәк рапорт бирик дип, акланмаган гамәлләр дә кылынды. Бигрәк тә авылдан кулак гаиләләрен сөргән чакта. Исеңә генә төшер, Кормаштан Нурлыгаян дигән кешене сөргән чакта, аңа карата гадел була алдыкмы? Җиде баласын урамга куып чыгарып, йортын советка тартып алдык. Ач-ялангач, йортсыз калдылар бит. Авыл халкы бәддога укыды безгә. Ишетмәгәнгә сабыштык. Андыйлар күпме җыела ил буенча?.. Шулай шул, без борын төбендәгеи күреп бетерә алмыйбыз, иптәш Сталин ил күләмендә уйлый, масштаблы фикер йөртә.

— Ничек ишетмәдек? — дип, гаҗәпләнеп сорады Фәйзуллин. — Директива буенча без Нурлый гаиләсен авылдан ук сөрергә тиеш идек. Шулаймы? Сөрдекме авылдан? Юк! Нурлыйның бертуганында сыену тапты алар. Без күрмәмешкә салыштык. Дошман элементларын төбетамыры белән йолкып атмаганга, авыллар кайный хәзер. Иптәш Сталин белеп яза торгандыр, анысына шигем юк, әмма аңлашылып җитми — күмәкләшү ирекле дә булсын, бөгелешләр дә булмасын, шул ук вакытта партиянең көзгә кадәр коллективлаштыруны төгәлләргә дигән күрсәтмәсе үтәлсен. Үз акылында булган крестьян өч атын, сука-сабанын, мал-мөлкәтен төяп: «Мине колхозга алсагыз сана!» — дип килерме безнең каршыга? Мәңге килмәячәк! Кормаш Нурлыйга килсәк, ул үзе гаепле. Совет кылган һәр гамәлгә каршы төшеп, комсомоллар белән бәйләнешеп, канга тоз салып ятты ул.

— Миндә башка информация бар. Кантком вәкиле Маловка Нурлыгаян абзыйның айгыры ошаган. Шуны тартып

аласы килгән икән. Шәп айгыр, туры айгыр... Синең дә күзең төшкән, диләр аңа.

Фәйзуллин җилләнеп сикереп торды.

— Соң, алай бик барысын да белгәч, өстән жалу яз, канткомга рисвай ит. Күңелең күкәй салыр, Нурлыйны да кире кайтарт. Малов белән туры айгыр хакында бәхәс булып алды булуын. Ну, аны нигә сөйләп йөрергә? Атны Маловка волком решениесе белән бирдек.

— Аны кире кайтарып булмый инде,— диде Әхмәтсафа, ачуы килеп.— Башбаштаклыкка юл куймаска иде. Малов дигән адәмне күргән юк әле.

— Белемен күтәрергә китте ул, җәйгә кайтып җитә. Кыю егет, шундый егетләр җитми безгә, тотса сындыра торган. Жәл, атын алып китте Минзәләгә. Менә хәзер кирәк булды ул, барасы җиреңә сәгать эчендә барып җитәсең, арттан җил генә сызгырып кала. Ә син беләсеңме, иптәш Дәүләтъяров, Кормаш халкының нинди явыз, усал икәнен? Әйтеп кенә ипкә килә торган халык түгел ул. Нурлый гел үзенекен генә тукыды, бөтен халык аның авызына карап тора, аның сүзе генә сүз иде. Менә бит ул ничек?! Һәр эшкә аяк чалып җәфалагач, башкаларга сабак булсын дип эшләнгән эш. И шулай булды да. Бераз артлары басылды. Шулай инде, эшләмәгән кеше генә ялгышмый. Әле алданиләр күрергә язган... Аннары шунсы да бар бит әле, без сине үзебезнең мөгаллимгә саныйбыз. Сез нәрсә ди торган идегез? «Җәмгыятьне тамырдан үзгәртеп корганда, аерым бер кешенең күргәннәре чүлдәге ком бөртеге дәрәҗәсендә генә булып кала, исәпкә бар, санга юк»,— диярга ярата идегез. Шулай булгач, кайдадыр Кормаш дигән бер авылда бала-чага үрчетеп яткан Нурлый исемле кешене авылдан сөрү социализм төзү эшенә тап булып төшә аламы? Юк, төшми!

— Горький сүзләрен мин бераз үзгәртә төшеп кабатлаган идем...

— Шунда шул хикмәт, Горький дөрес әйткән!

...Вакыйгалар көттермәде. Икенче көнне үк волость башкарма комитетына һәр авылдан махсус сайлап җибәрелгән кешеләр килә башлады. Һәркайсының кулында күмәк хуҗалыкка халыкның көчләп кертелүе хакында фактлар язылган кәгазь. Таләпләр охшаш — колхозларны таратырга, мәчетне мәхәллә халкына кайтарырга, мал-туарны, мөлкәтне хуҗаларына кире өләшергә! Ул арада идарә йортына Иске Кормаштан гөрс тонып комсомоллар — Газиз, Әбүш, Алатыр Мәрфуш килеп керделәр. Кыш көне дә кызыл яулыгын башыннан салмаган Мәрфуш, чая яшь хатын, волостьта хатын-кызлар арасында иң активы, чибәрлеккә чибәр булса да, бу минутларда тәмам төсен җуйган иде, аңа якын килергә, сүз

кушарга куркыныч, йодрыгын өскә күтәреп, авызыннан күбек чәчә башлады:

— Башларын Себер җибәреп бетерәсе калган икән, иптәш вәкил, авыл контрлар кулында! Тиз арада Минзәләдән гаскәр чакыртырга кирәк! — Ул, сүзен әйтеп бетермәстән, башыннан яулыгын тартып алып, почмактагы чиләккә капланып, голт-голт су эчә башлады. Бераз тынычлана төшеп, күзләрен алартып, як-ягына карап алды. Өлкә вәкиленең сүз башларга ашыкмавын күреп, янә чәчрәп, аның каршына килеп басты. — Контрлар активистларны чебен урынына кырып бетергәнче, чарасын күреп калыйк, иптәш Дәүләтъяров. Көч-хәл белән качып котылдык. Мәчетне клуб иткән идек, сөреп кенә чыгардылар безне, әле укытучы Әхәт Сәфәргалин белән ячейка секретаре Фатыйх Уразаев кайда йөри торганнардыр?.. Аларга бигрәк каныктылар, тотып, бәкегә салабыз, дип котырыналар.

Әхмәтсафа, югалып калуын белдермәскә тырышып, җай гына сораша башлады.

— Нәрсәдән риза түгел халык? Нинди таләп куялар? Ни өчен егетләргә каныгалар?

— Һы, әстәгыкәем, болай итеп утыра башласак! — Мәрфуш ишек төбендәге бүкәнне тибеп аударды. — Этем белгәнме аларның ни-нәрсә таләп итүләрен! Гәҗит укып котыралар. Иң беренче гәҗитне кем алып кайткан авылга, шуны судка бирергә кирәк! «Көчләп колхозга керттегез, җавапка тартабыз», — дип тузына халык. Картлар мәчет алдына җыелып тәкъбир әйтәләр, халык, амбарларны ачып, ашлыкны талап алып бетерде, озаклап, меж-меж килеп, сорау-җавап кичәсе үткәреп утырсак, монда да килеп җитәр алар. Тир түгеп төзегән колхозкаебыздан көл генә калды... — Мәрфуш үкереп елап җибәрде.

Башка авыллардан да шундый хәбәрләр килеп ирешә. Моңа Байсар, Әмәкәй, Мөслим волостьлары да кырмыска оясыдай кайный дигән хәбәр килеп өстәлде. Чыннан да, хәлләр хөрти, озаклап уйларга вакыт юк, шул ук вакытта эшне нәрсәдән башларга икәнен дә белеп бетереп булмый. Элекке кебек, гадәткә кергән кул каеру, боргычлау, көчләү сәясәтен эшкә җигү шикләндерә — иптәш Сталин ни дияр? Бәхеткә, канткомнан: тиз арада волость активын җыярга; икешәрләп бүленеп, авылларга таралырга, ярсыган халыкны тынычландырырга, газетта язылганнарны «дөресләп» аңлату эшен җәелдерергә дигән фәрман килеп төште. Кирәк очракта кораллы комсомол отрядын чакырып, хәбәр җибәрергә боерылган иде. Урындагы хәлләр өчен җаваплы итеп өлкә комитеты тарафыннан Әхмәтсафа Дәүләтъяров билгеләнүе дә күрсәтелгән.

Әхмәтсафа беренче чиратта чамадан тыш тынгысызлан-

ган авылларга активистларны җибәрү ягын кайгыртты. Иске Кормашка, «Үрнәк» колхозына, Фәйзуллин белән Дәүләтъяров үзе барачак иде, тагын ике кеше — Мари Суыксуында укытучы булып эшләүче үтә актив Миляев Морзагали белән комсомол әгъзасы Бусарин дигән егетерактагы Күҗәкә авылына бүген үк кузгалырга тиеш дип табылды. Башка активистларга да иртәгәге көнгә үзләре билгеләнгән авылларда булырга кирәклеге искәртелде. Колхозларны тараттырмау, мөмкин булганча мөлкәтне саклап калу бурычы куелды. Шуның белән утырыш тәмамланды, Әхмәтсафа белән Фәйзуллин юлга җыена башладылар. Аларга авылдан качып чыккан комсомоллар да иярде.

...Яз аеның ямьле көне иде бу. Әхмәтсафа төшлектән авышкан язгы кояшка күтәрелеп карады да, Оренбурда укыган елларын искә төшереп, күңеле кыбырсып куйды. Әле якында гына кебек, инде күпме сулар аккан, җилләр искән ул көннәрдән. Язгы бер көнне шулай Каргалыга җыелып кайтканнар иде алар. Арада Муса да бар иде. Юл буе шаярып-көлеп, әллә нинди эшләр майтарырга хыялланып, гәпләшеп чакрымнарны үткәнне сизми дә калганнар иде. Кич авыл яшьләре белән уеннар оештырдылар. Әйе, бар иде күңелле чаклар. Ул елларның авырлыклары онытыла бара, әйтерсең ачлык, иң якын кешеләрне югалтулар булмаган да, барысы да ал да гөл генә үтеп киткән кебек, шаулап торган яшьлек елларының якты мизгелләре хәтергә теркәлеп, тирән уелып калган...

Иске Кормашка ярты юлны үтеп барганда, каршыларына томырылып чабучы атлы күренде. Ат тотучы агай юртакны тыя төшеп, юл читенәрәк каерды. Каршыга килүче, алар белән тигезләшә башлагач, көч-хәл белән атын туктатты. Волость агрономы Осипов булып чыкты ул. Аты туктап җитмәстән, чанасыннан кар өстенә сикереп төште һәм куркынган тавыш белән ашыга-ашыга сөйләнә башлады:

— Иптәшләр, кире борылыгыз! Башыгыз ике булмаса, хәзер үк волостька ычкыныгыз! Гаскәрсез кереп булмый авылга, дулаган халык, кулларында күсәк тә сәнәк. Мин көч-хәл белән качып котылдым...

Әхмәтсафа үзе дә, юлдашлары да чанадан юлга сибелделәр, Осиповны урап алып, авылда нинди хәлләр булганын җентекләп сораша башладылар.

— Син каян анда барып чыктың? — диде Әхмәтсафа, гаҗәпләнгән кебек.— Җыелышта да булмадың...

— Харисов җибәрде мине Кормашка. Иртүк, халык аңга килгәнче җыелыш үткәреп, колхоз милкен саклауны оештыруны йөкләгән иде. Сакларсың, бар, авыл кешесе волостьтан мин килгәнне көтеп ята ди ул. Авылда бер актив калма-

ган,— ул ачу белән Мәрфушка карап алды.— Менә болар бик харап йөриләр иде дә көннәр тыныч чакта, кирәкләре чыккач, табып алырмын димә...

— Шулай да ниләр кыра алдың?

Осипов аты-юлы белән сүгенде.

— Бар, кырырсың син анда! Идарәгә килеп туктау белән чанадан өстерәп кенә төшерделәр. Баш бетте инде дигән идем. Халыкка бер дә начарлык кылмавымны искә алып, мин нәрсә, гомерем буе крестьянны җир эшенә өйрәткән кеше, бераз тәпәләп алдылар да келәткә ябып тоттылар. Ярый әле, атка тимәгәннәр. Өйлә намазыннан соң, картлар акылга килеп, кайтарып җибәрделәр менә.— Агрономның ике күзеннән сыпылып яшь чыкты.— Өемә исән-имин кайтып булмас инде дигән идем, насыйп булгач...

Осиповны кире борырга маташу файдасыз иде, аны кайтарып җибәреп, юлны дәвам иттеләр. Комсомоллар да шиңеп, бер авыз сөйләшми баралар. Кузгалып киткәч тә, бик батыр кыланып, бөтен контрны минут эчендә авылдан сөрү хакында җилкенеп кайталар иде. Мәрфушына кадәр тынып калды.

...Аларны авыл кырыенда унлап ир каршы алды. Кулларында күсәк. Волость вәкилләрен күргәч, юлны бүлеп, тезелеп бастылар. Ат тотучы агай атын туктата башлаган иде, Әхмәтсафа кесәсеннән наган тартып чыгарып, агайның җилкәсенә нык кына кагылып алды:

— Абзый, каушама! Мин ат алдына чыгам, арттан басып барсын атың... Без әйткәнне генә үтә, чамала аны!

Өлкә вәкиленнән калышасы килми, аның артыннан Фәйзуллин да иярде. Яшьләр чанада калдылар.

Гайрәтләнеп басып торган ирләр, каршыларына наган тотып килеп чыккан ике адәмне күргәч, югалыбрак калдылар шикелле. Шау-шу тынды, әмма шундук үзләрен кулга алдылар, арадан берсе, алгарак чыгып, вәкилләргә бер артын, бер алдын күрсәтә-күрсәтә, чинаган тавыш белән җырлап җибәрде. Кыюлык өчен моңа бераз әче бал эчергәннәр иде, ахры. Башкалар аны хуплап, куәтләп тордылар. Теге, тиле дигән саен, тигәнәк буе сикерүче адәм иде булса кирәк, аның саен шамакайлана, инде Әхмәтсафа белән Фәйзуллин алдына ук килеп җырлый.

Әхмәтсафа, тыныч булырга тырышып, алларында шамакайланган җырчы адәмне, читкә этәрә төшеп, алга атлады. Юл өстендә торган ирләр, кулына наган тотып, тәвәккәл адым белән үзләренә табан килгән кешенең Казан вәкиле Дәүләтъяров икәнен беләләр иде инде. Колхоз төзегән чакта ничә мәртәбә генә Кормашка килеп җыелыш уздырмады да, колхозга керергә үгетләмәде ул. Күпчелек халык шуның

сабыр, акыллы сүзләре аркасында гына керде дә инде күмәк хуҗалыкка. Менә хәзер ни әйтер ул?

Ирләрнең үзенә юл саба башлауларын күреп, эченә җылы йөгерде.

— Клубка барабыз, туганнар, җыелышыйк, сөйләшик,— диде ул, булдыра алганча тыныч тавыш белән. Бер күсәкләргә ым кагып, бер кулындагы наганга керфек кагып сүзен дәвам итте.— Боларны эшкә җиксәк, чамалыйсыздыр инде, ерак китә алмабыз...— Ирләр, күсәкләрен кысып тоткан килеш, шаулаша-шаулаша, Әхмәтсафага иярделәр.

Моңарчы клуб хезмәтен үтәгән мәчетне инде яшьләр кулыннан тартып алганнар икән, клуб дигән нәрсә калмаган авылда. Нурлыгаян дигән кешенең мәктәп итеп үзгәртеп корылган зур өенә җыела башлады халык. Өй эче тиз тулды халык белән, инде ишегалды ерып чыккысыз, әллә тагын якын-тирә авыллардан да килә тора кеше.

Өстәлне түргә үк күчереп, президиум сыман нәрсә әмәлләп, утырышырга өлгермәделәр, халык өстәл тирәсенә ябырылды. Һәркайсының кулында колхоздан чыгулары турында гариза. Өстәл өстендә минут эчендә кәгазь өеме пәйда булды. Өй эченә керә алмаганнар шаулаша-кычкырыша, гаризаларын башкалар аша тапшыралар, кәгазьнең вәкилләр кулына килеп керүен белергә тырышып, шау-шу кубаралар иде.

Көн кичкә авышканда, гаризаларны җыеп бетереп, көчхәл белән халыкны тынычландырып, җыелыш үткәрә башладылар. Идарә әгъзалары алгы рәттә идәнгә чүмәшкән. Фәйзуллин кычкырып гариза укый тора, тегеләр хәлсез, битараф тавыш белән: «Чыксын, чыксын...» — дип, авылдашларын күмәк хуҗалыктан чыгара торалар. Ярты төн җитеп килгәндә, «Үрнәк» колхозында барлыгы унбер хуҗалык калды. Халык таралыша башлады. Инде эш бетеп килгәндә, кинәт ишек каерылып ачылып китте, аяусыз тавышланып, кулларына күсәк тоткан берничә ир килеп керде. Берсе, алгарак үтеп, ачык итеп кычкыра башлады:

— Әгәр дә мәгәр халыкны колхозга көчләп керткән мөгаллим Әхәт Сәфәргалин белән мәчетне клубка әйләндергән денсез Фатыйх Уразаевны тотып бирмәсәгез, моннан исән-имин чыгу юк сезгә!

Фәйзуллин кулына наган тотып, өстәл артыннан сикереп торган иде, кемдер түшәмгә асылган лампаны күсәк белән бәреп төшерде. Өй эче дөм караңгы. Әхмәтсафа ни дип уйларга белми калды, башына күсәк белән китереп ордылар. Бәхетенә, бүреген киеп өлгергән иде һәм күсәк туп-туры түгел, аның башына эләккәнче, кемгәдер тиеп, бераз сугу көчен

киметкән иде. Бер генә мизгел исәңгерәп, почмакка табан елыша төште. Шул мәлдә үк уйлап та өлгерде, әгәр дә хәзер үк йорттан чыгып өлгермәсәләр, аларның җәсәдләрен генә алырга киләчәкләр волостьтан иртәгәсе көнне...

Ул, наганын чыгарып, түшәмгә атып җибәрде, болай да шау-шу иде, инде бөтенләй мәхшәр купты: кемдер җүләрләнгән шикелле кычкыра, кемдер чиный башлады. Әхмәтсафа өстәлне күтәреп, бүлмә уртасына ыргытты. Янәшәсендә Фәйзуллинны чамалап, аның җилкәсеннән умырып тотты да, тәрәзәгә табан өстерәп, әллә нинди ят тавыш белән: «Миннән калма!» — диде. Шул уңайда тәрәзә өлгесен тибеп ватты, тышка сикерде. Ишегалдында ниндидер күләгәләр йөгереште, ул көне буе халык таптап инде бозга әйләнгән сукмак өстенә дык итеп килеп төшүгә, мәтәлеп китте, тагын бер мәртәбә, чамалап, һавага атты. Өстеннән таптап диярлек Фәйзуллин йөгереп үтте. Ул да берничә мәртәбә наганнан гөрселдәтте. Ни сәбәптәндер алар артыннан берәү дә тышка сикермәде. Кеше-фәлән дә күренми. Күсәк тотып наганга каршы һичкемнең бергә-бер чыгасы килми иде, ахры. Әхмәтсафа ирексездән башын югары күтәреп карады. Анда аңа табан, шыксыз елмаеп, ай карап тора иде...

Волость үзәгенә таң атканда кайтып керделәр. Алар артыннан Күҗәкәгә киткән Миляев белән Бусарин кайтып төштеләр. Миляев башын яулык белән бәйләгән, яулыктан кан саркып тора. Аларны да Күҗәкәдән тукмап җибәргәннәр, болары көч-хәл белән качып котылуларына, исән кайтып җитүләренә сөенеп бетә алмыйлар.

Икенче көнне Иске Өшәрдә халыкның советка буйсынмавы, алай гына да түгел, беренче категория белән авылдан сөрелгән Габдулла Арсланов дигән кешенең гаиләсен яклап, хатынын, балаларын авылдан чыгарып җибәрттермәү өчен чын-чынлап көрәшкә күтәрелүе турында хәбәр килеп иреште. Әгәр тиз арада чара күрелмәсә, монда кан коелачак тек коелачак иде. Иртән бераз черем итеп алырга өлгергән Әхмәтсафа Дәүләтъяров, эшләрнең зурга китүен чамалап, кораллы ярдәм сорап, Минзәләгә кеше җибәрде. Миляевны чакырып китертте, аңа авылдагы комсомоллардан отряд тупларга, корал табарга йөкләнде. Көн уртасына кадәр киеренке оештыру эшләре белән мәшгуль булды, тамак ялгап алырга утырган иде, волость идарәсенә кош токандай Миляев атылып килеп керде.

— Фәрман үтәлде, иптәш вәкил,— диде ул, керә-керешкә кычкырып.— Отряд сезнең карамакта!

Әхмәтсафа, өстенә шинелен бөркәнеп, ишегалдына чыкты. Идарә каршында аркаларына ау мылтыклары аскан ун

егет һәм бер хатын-кыз. Хатын-кыз дигәне Кормаштан Мәрфуш иде. Ул инде авылына кайту хакында уйламый да, совет өчен җанын да бирергә әзер булып йөри. Хәер, аны авылга кертмиләр дә, авылдашларының канына шактый тоз салырга өлгергән, күзләренә күренсә, хәзер тукмап ташлаячак аны халык.

Күңеле күтәрелде. Баш сызлавы басылды кебек хәтта. Отрядтагылар атка атланганнар, әмер генә көтеп торган сыман. Ул тиз генә идарәгә кереп, киенеп чыкты да отряд башында Иске Өшәргә юл тотты. Уйга ирек кенә бир, гаярь егетләре белән Каргалыга килеп кергән Шамил Усманов исенә төшеп, көлемсерәп куйды. Хәлләр тагын катлауланып китте бит менә, инде совет хакимияте тәмам җиңеп, моның ише отрядлар кирәклеге башка да килмәгән чакта, мә, күрмәсәң күр дигәндәй, тагын коралга тотынырга туры килә. Крестьянның күңел түренә үк кереп утырган милекчелек психологиясен кайчан да булса тулысынча җиңеп булырмы?.. Ичмаса, Шамил Усманов чын бөркеттәй егетләргә баш иде, анда хәрби тәртип, сыналган, тәҗрибәле сугышчылар иде аның отрядында. Ә ул кемнәр белән контрга каршы бара? Ихахайлап кычкырып йөргән Мәрфушларны җыеп...

Иске Өшәрдә хәлләр, чыннан да, җитди иде. Авылга килгән өч ГПУ кешесе чарасыз калган. Совет Габдулла Арслановның хатынын балалары белән мунчага сөреп чыгарган булган. Аларны авылдан куарга ГПУ килүен сизенгән халык, дәррәү күтәрелеп, мунчаны камап алган да аңа беркемне дә якын җибәрмиләр. Бигрәк тә авыл хатыннары чая кылана. Кулларында сәнәк. Алар мунчаны әйләндереп, камап алган. Читтәрәк җыелып торган ирләр күсәкләр, иске ау мылтыклары белән коралланганнар. Берничә урында имән казыкларны очларын өскә каратып «кәҗә»ләр ясап куйганнар. Алар янында ирләр сакта тора, якын килеп кара!

Әхмәтсафа килгән уңайга ирләр белән сөйләшмәкче булган иде, аларга якынлашырга өлгермәде, шартлап мылтык атылды. Баш очыннан гына ядрәләр сызгырып үтте. Үзе дә сизмәстән җиргә чүкте. Әйләнеп караса, ат өстендәге отряд җиргә сибелгән, кымшанмый да яталар. «Болар белән яуга чыксаң...» Әхмәтсафаның күңеленә килгән хәсрәтле уй аны айнытып җибәрде, ул тиз генә калкынып, тагын ирләргә каршы китте. Ирләр чигә төшеп, сагаеп аны каршы алдылар. Шактый дәшми, карашып торгач, өлкә вәкиле ни өчен килүләрен аңлатырга тотынды. Каршылык күрсәтүнең файдасыз нәрсә икәнен төшендерергә керешкән иде, мунча янындагы хатыннар разбой салып кычкырырга тотындылар:

— Үтерәләр, нәрсә карап торасыз, безгә мылтык төзиләр!

Нәрсә карап тора бу ирләр? Үтерәләр! — Чыннан да, ГПУ гаскәриләре, мылтыкларын алга сузып, мунчага якынлашып киләләр иде.

Хатыннар отыры кычкыралар, разбой салалар

— Нәмә карап каттыгыз? — Бусы ирләренә төбәп атылган сорау иде.— Күрмисезмени, итәк астына кереп, бөтен җирне актарырга маташалар солдатлар! Коткарыгыз, талыйлар, көчлиләр!

Минут эчендә барысы буталды. Авыл ирләре, хатыннарының кыздыруына түзә алмый, отряд өстенә ташландылар. Туктаусыз кычкырыш, мылтык тавышлары астында отряд авыл читенә чигенергә мәҗбүр булды.

Кичкә табан Минзәләдән кырык сигез кешелек коралны комсомоллар килеп кенә, Габдулла Арслановның хатынын авылдан алып чыгып, Минзәлә төрмәсенә алып киттеләр. Әхмәтсафа үз өстенә Ходай да, бәндә дә кичермәячәк янә бер гөнаһ алды...

Әхмәтсафага исә Минзәләгә кайтып китү насыйп булмады. Отряд командиры аңа кантком күрсәтмәсен җиткерде: Әмәкәй волостена кергән авылларда күпләп колхоздан чыгу башланган. Хәлне урынга барып тикшерүне һәм колхозларны таралып бетүдән саклап калырлык кичекмәс чаралар күрүне оештыруны, өлкә комитеты вәкиле буларак, аңа йөкләгәннәр иде. Әхмәтсафага ярдәмгә ун кешелек коралны җайдак бирелде, ул шул ук көнне, умарта күче кебек тузгыган бу төбәкне калдырып, юлга кузгалды. Өшәр тирәсендәге авылларда кантком карары үтәлеп, шактый кешене төрмәгә озату һич тә совет властеның яңа тормыш төзү юлында аерым казаныш, җиңү дип саналырлык нәрсә булмавын тоя башлаган Әхмәтсафаны күңелсез уйлар биләп алды. Мондый аяусызлык белән халыкны сыйнфый катламнарга аерып, акыллы, гаярь дип саналган һәркемне читкә сөрә башласак, кемнәр калыр авылларда, колхозларны кемнәр белән төзерләр, советны нинди кадрлар белән ныгытырлар — менә шушы гап-гади сорауларга җавап таба алмый иде ул. Юкса аның хәлендәге кешегә сөенергә генә кирәк, шушы өч-дүрт көн эчендә генә дә әле менә үз язмышлары өчен борчылып барган «акыллы һәм гаярь» адәмнәр аны ничә мәртәбә теге дөньяга озата яздылар. Ничек исән калгандыр — бер яктан, үзенең үтә сак, икенче яктан, кыю һәм тәвәккәл адымнары каршы көчләрне иң кирәк мизгелдә каушатып калдырдымы, әллә Рабиганың саф, керсез күңелдән теләгән изге теләкләреме, боларын аңлау-аңлатудан гаҗиз иде ул. Белгәне шул — һәр ике яктан кирәкмәгән кан коела, тиешсез гамәлләр кылына. Шушы вакыйгаларның уртасында ул — Дәүләтъяров кай-

ный. Ул бу казанны ташлап чыгып та китә алмый, анда бер генә минутка каласы да килми. Тик моны кемгә әйтергә? Кемгә аңлатырга һәм моны кем дә булса тыңлап, зиһененә сеңдереп торырга теләк белдерерме? Ай-һай. Бүгенге көндә колхозлашу хәрәкәтен тизләтү максаты белән адарынган бер генә кешенең дә, тын алырга тукталып, болар хакында ныклап уйланасы, баш ватасы килмәс. Алга, алга, җиңү арты җиңү, үр арты үр яуларга чакырулар... Ниндидер иблис бөтен илне, дөньясын алга куалый да куалый, тын алырга да ирек бирми иде.

Бу көннәрдә кичерешләр, тетрәнүләр күп булды, әмма хикмәтле хәлләр алда икән. Төнне Байсарда үткәрү нияте белән совет йортына якынлашып килгәндә, аны кораллы солдатлар туктаттылар. Тикшерү, сорашу китте. Баксаң, инде ике-өч көн бу якларда солдатлар ияртеп өлкә комитеты вәкиле Сәгыйтов дигән кеше йөри икән. Дәүләтъяров, батыраеп, совет йортына үтмәкче иде, өйалды тулы хатын-кыз күреп тукталып калды. Алар, кораллы кешене күргән уңайга куркышып, түр стена янына сылаштылар. Үзләре мышкылдап елашалар да иде.

— Ни хикмәт монда? — дип сорады ул үзен озатып кергән солдаттан.— Бу хатыннар ни эш кыралар монда? — Өшәрдәге хәлләрдән соң ул хатын-кыз затыннан шүрли дә төшкән иде.

Солдат, артык җәелмичә:

— Вәкил иптәш чакыртты аларны,— дип, өй ишеген ачып җибәрде.

Тупсаны атлап кергәнче үк Әхмәтсафаның йөзенә кызу һава бөркелде. Лампа яктысында күн пәлтә кигән берәү кәпераеп йөренә, үзе өй уртасына баскан чәчләре-башлары тузгыган ике хатынга карап туктаусыз җикеренә иде:

— Сук, сук, жәлләмичә сук. Ул сине жәлләп тормады бит, ә? Катырак тамыз, катырак, дим!

Әхмәтсафаның абайлап алганы шул булды: хатыннарның кулында кыска таяк, алар, «сук» дигән саен, бер-берсенә кизәнгән булып кыланалар, һич кенә дә ныклап сугарга кыймыйлар иде.

Бу кешенең тавышы бик таныш иде. Әхмәтсафа ныклап танып өлгергәнче, теге кеше ишектән тартынусыз килеп керүчеләргә кисәк адым ясап, шып туктап калды. Әхмәтсафа аның кулындагы наганның нәкъ үзенә төбәлгәнен генә чамалап өлгерде.

— Үзебезнекеләр! — Солдат, аңлашылмаучылык килеп чыкмасын диптер инде, кисәтүне кирәк тапты.

— Кемнәр ул «үзебезнекеләр»?

Әхмәтсафа каршысындагы каратут йөзле, күзләре калайланып янган, авыз читләреннән күбек бәреп чыккан кешенең Фатыйх Сәгыйтов икәнен танып өлгергән иде инде, җиңел сулап:

— Мин әле бу, Дәүләтъяров... — диде.

Сәгыйтов баштарак аптырап калса да, үзен тиз кулга алды:

— Нинди җилләр ташлады сине монда? — диде ул.

— Өлкә комитеты вәкиле итеп җибәрделәр. Колхоз төзү эшләре белән чабабыз.

— Төзисез, пычагым, — дип, ачу белән кычкырып җибәрде Сәгыйтов. — Аның хәл-әхвәл сорашып, сөйләшеп торасы килмәгәне сизелә иде. — Менә ничек төзиләр ул колхозны! — дип әйткән уңайга хатыннарның өлкәнрәгенә аяк тибеп кычкыра-кычкыра, өстенә килә башлады. — Нәрсә бәбәгеңне киереп торасың? Сук, дим мин сиңа, сук ахирәт абыстаеңа! Колхозны таратырга өндәгән чакта кыланган сыман, җәһәт бул!

Хатынның йөзеннән тир катыш яшь ага иде, сулкылдыйсулкылдый Сәгыйтовка ялына башлады:

— Нишләп мин кеше котыртыйм ди? Җә инде. Кеше кайгыларымы миндә, иремне төрмәгә алып киттеләр, өйдән куып чыгардылар, балаларым ач, ялангач, кеше абзарларында кунып йөрибез. Зинһарлар өчен, җәфаламагыз ла... — Ул, күз яшьләренә буылып, Сәгыйтовка табан бер адым атларга өлгермәде, өйне наган тавышы яңгыратты. Хатыннар гына түгел, моңарчы ишек төбендә утырган адәм дә идәнгә лапылдап ауды.

— Базда катырып үтерәм мин сине, хәшәрәт! — дип, Сәгыйтов өй базын ачарга азаплана башлады.

Болай карап тору мөмкин түгел иде, Әхмәтсафа шактый кискен итеп Сәгыйтовка эндәште:

— Җитте, Фатыйх! Нәрсә кыланасың, понимаешь, кем сиңа рөхсәт бирде халык белән болай эш итәргә? Хәзер үк кайтарып җибәр бу хатыннарны!

Сәгыйтов, калтырана-калтырана, әле генә кесәсенә салып куйган наганын кармалый башлады. Әмма Әхмәтсафаның да кулында наган күреп, нигәдер чүгә төште.

— Син нәрсә-ә, Дәүләтъяров, миннән үч алырга килдеңме монда? Элеккеләрне искә төшерәсеңме? Уңай вакыт таптың... Миңа боерык бирергә кем әле син ул хәтле?

— Беренчедән, синең кебек үк өлкә комитеты вәкиле, икенчедән, партиянең кантком работнигы. Менә син үзең ничек килеп чыктың монда, кем җибәрде?

— Партия җибәрде! — дип кәперәеп маташса да, инде Сәгыйтовның кикриге шиңгән иде. Ул арыган тавыш белән хатыннарга эндәште. — Аунамагыз, анагызны... — Аяк өсте-

нә күтәрелгән адәмгә әмер бирде.— Олактыр боларны, күзем күрмәсен.— Аннан Әхмәтсафага борылды.— Синең белән дә сөйләшербез... Мин ал-ял белми таралып беткән колхозларны кире җыеп, укмаштырып йөрим, син өлкә комитеты мандатын калкан итеп, астан ут йөртәсең икән. Аңлашылды...— диде ул теш арасыннан.

— Куркытма, Фатыйх, бер-беребезне куркытышлы уен уйнар чак түгел. Хәлләр җитди. Син килгәнгә ике-өч көн, ни өйрәндең, ни белдең ул арада? Кораллы солдатлар белән килеп, халыкны куркытып, колхозга куып кертергә булыр да булуын, иртәгесе көнне нәрсә көтә монда? Миңа бу төбәктә хәлләр яхшы таныш, һаман да халыкны көчләп колхозда тотуны дәвам итсәк, ахыры хәерле бетмәячәк. Аң бул, ут белән шаярасың!

— Ни кылырга кушасың инде? Күрә торып колхозларны таратып бетерикме? Өлкә комитеты, кантком шуның өчен җибәрдеме сине монда? — Сәгыйтов һөҗүмгә күчеп маташа иде.— Мин шушы ике көн эчендә Түбән Яхшыйда, Табанлыкүлдә, Мәчтидә таралып беткән колхозларны кире торгыздым. Кире уйлап карасыннар...

— Ничек тиз генә җыясы иттең аларны? — Әхмәтсафаның тавышында ирония сизелеп китте.— Шулай абыстайларны бер-берсе белән сугыштырыпмы?..

— Анысы да булды.— Сәгыйтов тагын кәперәеп сөйләнә башлады.— Өлкә комитеты белешмәсендә ачык язылган — минем вәкаләтләр чикләнмәгән. Бездән барысы да дер калтырап торырга тиеш! Нигә әле без җыен кулак, мулла-мунтагай хатыннарын колхоз төзү эшенә җикмәскә тиеш? Ничек эшлим дисеңме? Килеп керәм авылга. Совет аша бөтен ирләрне җыеп келәткә яптырам. Куркыту өчен солдатлардан берике мәртәбә залп бирдертәм келәт төбендә, шыр җибәрәләр инде, малай. Кстати, сыналган ысул бу, күп җирләрдә шулай эшлиләр. Аннан җыям совет йортына хатыннарын. Кулак, мулла хатыннарын башкалар алдында бер-берсе белән сугыштырам, талаштырам, тыңламаска маташсалар, колак төпләрендә генә наган гөрселдәтәм, шуннан китә эш хутка. Кем кире колхозга керә, алар гаризаларын калдырып кайтып китә, каршы килүчеләрне базга ябып куям. Минем һәр авылда ун-унбиш кешем базда ята уйланып...— Мактанганда Фатыйхның авыз кырыйларыннан күбек бәреп чыкты.

— Да... Ишкәнсең икән ишәк чумарын...

— Син моның ишегә каршы инде, әйе бит.— Сәгыйтов ачыктан-ачык үчекләшә иде.— Вчүтеки, сине бу эшкә җибәреп ялгышкан өлкә комитеты. Кемнең кем икәнен белми торып...

— Әйдә, сүз көрәштереп вакыт үткәрмибез. Бәхәсләшеп тә торасы юк — халыкны судсыз-нисез келәткә, базга ябып кую өлкә комитеты вәкиле эше түгел. Без урыннардагы партия оешмаларына ярдәм күрсәтергә тиешбез. Менә бу эштә безнең вәкаләтләр чикләнмәгән, әлбәттә. Нигәдер монда ни партия оешмасы сәркатибен, ни башка активны күрмим.

— Халыкны җыярга куштым мин аларга. Берәр буш келәткә кертеп тутырырга...

— Менә ничек! Хәзер үк син кыланганнар буенча ашыгыч чаралар күрергә, вазгыять контрольдән чыкканчы, хәлне төзәтергә кирәк. Беләсеңме, авылларда каршылык нинди төс алып бара? Безнең ялгыш адым ясаганны көтеп торучылар юк дисеңме? — Ул ишек төбендә тавыш-тынсыз утырган кешегә дәште. — Сез кем буласыз?

— Күмхуҗ рәисе идем лә...

— Ничә әгъза калды күмхуҗда, таянырлык кешеләрең бармы? Чыгасы килгәннәр, әгәр инде үгет-нәсихәтләр ярдәм итмәсә, чыга бирсенәр, ә үзәкне, умыртка баганасы булырдай көчләрне сакларга кирәк. Менә шундый дуамаллык күреп, барысы да качышып бетмәсен күмәк хуҗалыктан.

— Егермеләп хуҗалык нык тора әле, колхоз кирәк дип йөрүче кызыл партизаннар күпчелеге.

— Шуларга таянып эш йөртегез. — Дәүләтъяровның тавышы йомшара төште. — Халыкны тынычландырырга кирәк беренче чиратта. Чәчүлек орлыгы салынган келәтләрне туздырта күрмәгез, көн-төн саклау оештырыгыз. Яз көне чәчүлек орлыксыз калсагыз, эш мөшкелләнер. Язгы чәчү күрсәтергә тиеш күмәклек көчен, шуңа кадәр сабыр итәргә кирәк. — Ул кисәк Сәгыйтовка борылды. — Сиңа, Фатыйх, теге авыллардан кабат үтәргә туры киләчәк. Анда хәзер нинди хәлләр икәнлеге миңа караңгы, йоклап ятмый торганнардыр. Инде кыланып күрсәткәнсең, хәвеф-хәтәрсез Минзәләгә кайтып керүеңә ышаныч юк, ал минем биш кораллы җайдакны, тоткыннарыңны азат ит һәм күп сүзгә җитми авыллардан чыгып сыз. Мин моны сиңа канткомның җаваплы работнигы буларак әйтәм.

— Ә син?.. Без бергә китмибезмени? — дип сорады Фатыйх, куырыла төшеп. — Миңа бит Минзәләдән йөз кешелек кораллы отряд җибәрәбез, дигәннәр иде ярдәмгә. Алар килмичә, мин беркая да китмим. Көтәргә вакытым бар әлегә.

— Кабатлап әйтәм, контонда хәлләр катлаулы, беркем дә, менә бүген сиңа ярдәм кирәк дип, отряд җибәрмәячәк. Алар хәзер һәркайда кирәк.

Сәгыйтов нигәдер Дәүләтъяровка каршы төшәсе итмәде. Әллә чынлап та ныклап арыган идеме, әллә үзе тынычлыгын

алган авыллар аша кабат үтү кирәклегенең котылгысызлыгы яңа башына барып җитте, мич янындагы чиләктән чумырып су алды да чапыр-чопыр эчә башлады…

…Әмәкәйгә икенче көнне төш турысында килеп керде алар. Әхмәтсафа туры каравыл өенә китте. Анда, ул көткәнчә, халык төркеме шәйләнмәде күзенә. Авыл үзе дә ничектер тыныч, ниндидер бер җиңеллек белән язгы кояш астында сизрәп утыра иде. Каравыл йортына ни кергән, ни чыккан кеше күренмәгәч, күңеле тынычсызланып куйды Әхмәтсафаның. Хәвефләнеп, әле гаскәриләр атларыннан төшәргә өлгергәнче, ашыга төшеп эчкә үтте.

Йортның сыңар тәрәзәсе янындагы япмасыз өстәл янында нидер язып Габитов утыра. Ул, керүчегә бөтенләй игътибар итмәстән, аның кычкырып биргән сәламен дә алып тормыйча, өстәл астыннан кәгазь белән яртылаш тулган иске кәрҗинне тартып чыгарды да аягы белән ишек ягына шудыртып җибәрде.

— Гаризаңны шу-унда ташла, апай — диде ул, искитмәгән кыяфәт белән.— Хуш, фамилияң ничек димме инде…

— Дәүләтъяров…— Габитовны исән-имин күргәч, тын алуы иркенәеп киткән сыман тоелды.— Ул-бу юк бугай монда…

— Дәүләтъяров… тәк-тәк… Дәүләтъяров дисең инде син… Эзләп тап инде менә шушы мунчаладан Дәүләтъяров дигән кешене…— дип сөйләнә-сөйләнә, Габитов, тәрәзә ягына авышып, бер учма кәгазь актара башлады. Ул әле һаман Әхмәтсафага күтәрелеп тә карамый иде.

Аның бу хәлгә ачуы чыгасы урынга, шаяртасы килеп китте.

— Эзләмә, иптәш Габитов, минем фамилияне, ерак яшеренгән ул.

Габитов ялт башын күтәреп карады, кантком вәкилен төсмерләп, утырган эскәмиясеннән сикереп торды.

— Карале, апай, бөтенләй эшкә мавыгып киткәнмен…— диде ул, төче тавыш белән.— И-и иптәшкәй Дәүләтъяров килеп чыккан икән бит безгә. Ничекләр киләсе иттең, әле үзем утырам, үзем ямансулыйм, колхозны шартлатып төзеп куйганда, зур-зур кешеләр килде Минзәләдән, мин әйтәм, күмхуҗ таралганда, берьялгызым утырам каңгырып. Менә сине күргәч, күңелләр күтәрелеп китте бит әле, иптәш Дәүләтъяров…

Әхмәтсафа сорау бирәсе итте:

— Ничек, әллә колхоз таралып та беттемени?.. Бик тиз…

— Бетте, иптәш Дүләтъяров, бетте күмхуҗ,— диде Габитов, пошмас тавыш белән.— Күмхуҗ менә шушы кәрҗиндә инде хәзер. Каршы төшеп булмый, иптәш Дәүләтъяров, кил-

гән берсе иптәш Сталин мәкаләсен күтәреп керә гаризасы белән. Иптәш Сталинга каршы килеп булмый гына бит, апай, сәяси ялгыш китмәсен дип, башны да күтәреп карамыйм, исемлеккә язып куям да, вәссәлам.

— Чынлап та бер кеше дә калмадымыни колхозда? — дип аптырап сорамый булдыра алмады Әхмәтсафа. — Инде шулкадәр макталып, телгә кергәч, аз гына да саклап калу хакында уйламадыгызмы күмәк хуҗалыкны?

— Берәү калды исемлектә... — диде Габитов, теше сызлаган кешедәй йөзен җыерып. — Йөз процент таралды дип булмый булуын.

— Кем ул?

— Сөләйман карт, — диде Габитов, ыңгырашкан тавыш белән.

...Әмәкәйдән ул янә туры Суыксуга юл тотты, аңа курсларны дәвам итү йөкләнүе хакында фәрман килеп иреште. Егерменче мартта аны Минзәләгә чакырып алдылар. Партиянең кантком конференциясе булып, аны пленум составына керттеләр. Пленумда исә тагын да югарырак күтәрелде, ул бюро әгъзасы, агитация-пропаганда бүлеге мөдире итеп сайланды. Авылларда колхоз төзү икенче төс алды. Әле февраль ахырында ук Минзәлә кантком Казанга йөз процент күмәкләшү турында рапорт биргән иде, март ахырына бу сан күпкә ким иде инде...

Әхмәтсафа конференциядән соң атналар буе авыллардан кайтып кермәде. Бу көннәр хакында киләчәк буыннарга көндәлектәге язмалар гына сөйләр инде: *«Утызынчы мартка кадәр көн-төн, армый-талмый, ташка куйсаң, таш ватарлык көчләр биреп, «ни один колхозник не должен выйти из колхоза» диелгән кантон конференциясе директивасын утәргә тырышабыз-тырмашабыз.*

*Колхозларга каршы хәрәкәтнең иң кутәренке вакыты егерме икенче марттан утыз беренче мартка кадәр булып, аның куп урыннарда советларга каршы хәрәкәт төсен алуы, шуның нәтиҗәсендә авыл советлары, хәтта волостьның вазгыятьне кулдан ычкындыру куренешләре сизелде. Менә шушы тынычсызлыклар, переживаниеләр бер вакытта да онтылмаслар. Нервларга ясаган эзләре мәңге калыр, сакланырлар...»*

...Ничек кирәк алай күмәкләшүне нигездән җимерми саклап калып, язгы чәчүләрне үткәреп җибәрделәр. Әхмәтсафа инде язмышына буйсынып, шушы якларда төпләнү ягын да уйлый башлады. Җәй урталары җиткәч, Рабиганы да монда алып килү иде исәбе.

Минзәләдә, беркөнне фатирга кайтып барганда, аңа Шәмтиев очрады.

— Нихәл, иптәш Дәүләтъяров, колхозларны җимереп бетерәсеңме әле, үгет-нәсихәт мөдире? — дип шаярта төшеп, асылда, мыскыллаган кебек сөйләнә-сөйләнә, кул бирде ул Әхмәтсафага.

— Колхоз төзү эшендә кимчелекләр булган икән, анда барыбызның да гаебе җитәрлек,— диде Әхмәтсафа, тегенең шаяртуын өнәмичә.

— Серкәң су күтәрми икән, дус кеше,— дип, Шәмтиев борын җыерды.— Болай гына әйтү, авылларда синнән дә күп йөрүче булмады бит ул чорда. Шул искә төште. Менә син турыдан-туры шул ялгышларны җибәрдең дә инде. Алай да сине пленум бюросына сайлап куйдылар...— Шәмтиевнең тавышы рәнҗүле иде.— Мин дүрт-биш авылга барып кайттым, арттан бер жалу килмәде, тора салып пленум составыннан чыгарып аттылар. Гаделлекме бу, тик торганда урыннан төшерүне әйтәм?..

— Үзең үк әйттең, тик торганга төшкәнсең дә инде,— дип көләсе итте Әхмәтсафа.— Түрдән төшү гүргә төшү түгел әле ул, аптырап йөрмә юк өчен.

— Сиңа көлке,— дип, һаман үпкәләвен сиздереп сөйләнде Шәмтиев.— Сиңа җайлы, тиз онытасың авырлыкларны. Бер малай әтәсенә: «Сугыш бетте, әтәй, сыерны суеп сатыйк та гармун алыйк, мин уйнармын, син җырларсың»,— диеп әйткән ди. Үпкә саклап та йөрмисең, сүзне уен-муенга әйләндерергә һәвәс, ачуланышыр чакта...

— Аңламыйм, нигә, кем белән ачуланышып йөрим ди? — дип, чынлап сорады Әхмәтсафа.— Болай да башлар катып бетте. Бер сүз сөйлибез, икенчесен эшлибез...

Шәмтиев шуны гына көтеп торган диярсең, йөзе ачылып китте. Ул сынаулы караш ташлап, пышылдап диярлек, сорау бирде:

— Нәрсә, иптәш Дәүләтъяров, партиягә ышанып бетмисеңме әллә?

— Каян алып әйтәсең?

Шәмтиев каш сикертеп алды.

— Икеле-микеле сөйләшәсең... Шуңа әйтәм...

— Төрле вакыт була торгандыр инде.— Әхмәтсафа сүзне озынга җибәрми китеп бармакчы иде, Шәмтиев аны туктатты.

— Мин бит болай гына, иптәш Дәүләтъяров. Синең кебек укыган кеше түгел шул без, кайбер нәрсәләрне аңлап та бетми торганбыздыр. Сорыйсы гына килә, шулай да дөресен генә әйт әле, колхозлаштыруны дөрес дип табасыңмы син?

— Дөресен әйт дисеңме? — Әхмәтсафа, тын калып, Шәм-

тиевкә сынаулы караш ташлады.— Нигә кирәк соң сиңа аның дөресе?

Шәмтиев, авыз читен кыйшайтып, елмайгандай итте.

— Авыллар нык каршылык күрсәттеләр бит, шуңа гына әйтүем...

Әхмәтсафа үзе дә сизмәстән ачылып китте.

— Дөресен әйткәндә, күмәкләштерүне яклаган хәлдә, мондый ашыгуны хупламыйм. Кулак дигән булып, авыллардан иң тырыш, булдыклы кешеләрне сөреп бетерүгә дә каршы идем. Авыл фәкать шундый кулыннан килә торган кешеләре булганда гына күтәрелә ала. Кайбер хәлле кешеләрне кулак дип, колхозга алмый, хәлне кискенләштерү ягында да түгел идем. Ни эшлисең, фирка карары һәр коммунистка канун, үз-үземне җиңеп, карарларны кулдан килгәнчә үтәргә тырыштым...

— Вәт, вәт, әйтәм бит, укыган кеше бөтенләй икенче төрле сөйли шул...

Шәмтиевкә шул гына кирәк иде, ахры, саубуллашмый да китеп барды. Бу сөйләшүне Әхмәтсафа тиз онытты, моны еллар үткәч исенә төшерәчәкләрен дә чамаламый иде әлегә...

Фатирга кайтып, ашарга өлгермәде, олы конвертка салынган хат китереп бирделәр. Айхенвальд, аны университетка кайтып, аспирантурада укуын дәвам итәргә үгетләп, хат юллаган. Тәкъдиме коры сүз генә түгеллеген раслагандай, хат белән бергә ТКУ директоры Вольфович имзасы белән ныгытылган чакыру да җибәргән иде. Өстәвенә партия өлкә комитетыннан да ризалык язуы алынган, анысы да конверт эчендә. «Хәзер фәнгә яшьләр кирәк. Синең кебек тәҗрибәле, белемле яшьләргә мохтаҗ ил. Икеләнмә, эшләргә өлгерерсең, мин Ишков, Разумовский, Слепков, Эльвов иптәшләр белән дә киңәштем, барысы да синең кандидатураны яклыйлар. Тулай торактан гаиләләләр өчен бүлмә бирербез. Хатының белән бергә яши башларга кирәктер бит инде, наконец!» — дип, егетнең күңелен канатландырган сүзләр дә теркәлгән иде хатта. Өлкә комитет исеменнән җибәрелгән юлламага кем каршы килсен?! Җәй башында район (канткомнар бетерелеп, районнар төзелә башлаган иде) үзәгеннән аны ат белән Курья пристанена китереп куйдылар...

...Казан Әхмәтсафаны якты йөз белән каршы алды. Алда яңа тормыш көтә аны; яңа дуслар, яңа омтылышлар, яңа ачышлар кочагында нинди биеклекләргә күтәреләсен Әхмәтсафа Дәүләтъяров әле күз алдына да китерә алмый иде. Әлегә Рабигасы янына ашкынып кайтып җитте дә, гомеренең

иң татлы мизгелләре өермәсендә эреп, югалып калды. Ниһаять, ничә еллардан соң алар бергә, алар бәхетле, йолдызлар төнге күкне алар өчен генә бизәп калкалар, ай аларның сәгадәтле минутлары сагында тора, кояш аларга гына елмая иде кебек...

Шундый нурлы, якты төннәрнең берсендә Рабига Әхмәтсафаның колагын кайнар сулышы белән өтеп алды:

— Мин сиңа бер малай алып кайтам...

— Чынлапмы, сөеклем?! Болай булгач, яшибез! Дәүләтъяр нәселе исән, яши дигән сүз! Рәхмәт, кадерлем!

Әхмәтсафа үзен-үзе белештермичә урыныннан сикереп торды, Рабиганы көчле кулларына күтәреп алды да бүлмә буйлап зыр китереп әйләндереп йөртә башлады. Бәхете ташыган Рабига иренең муенына сарылды, аның керфек очларына эленгән күз яшьләрен иксез-чиксез күктә йөзгән тулган ай гына шәйләп алса алгандыр... Бу төндә меңнәрнең бәхеттән очынуларына, меңнәрнең бәхетсезлектән канатлары каерылуына шаһит иде ай. Бәхет белән бәхетсезлек, шатлык белән хәсрәт, табу белән югалтуның гаҗәп дәрәҗәдә янәшә барулары — дөньяга адәм баласы яралган көннән барлыкка килгән һәм һичнинди үзгәреш кичермәгән хакыйкать бит ул.



# Өченче китап



# ЯЛГАН ТӘРӘЗӘЛЕ ЙОРТ

Таш ташлады. Батты. Төбе юк.
Сүз эндәште — җавап өне юк...

*Мостай Кәрим*

## I

Казан капкасын кыш җиле кага...

Мең тугыз йөз утыз җиденче елның егерме тугызынчы ноябре. Еракта уйнаклаган кызгылт таң нурлары, офык түренә катлы-катлы өелгән кара-кучкыл тыгыз болытларны ермачлап, дөньяга яңа көн туып килүен хәбәр иттеләр. Кар сибәләп алды. Казан урамнары суыктан бөрешеп калган, әллә тагын кыш беренче мәртәбә килә бу җиргә — бөтен шәһәр көтелмәгән мөшкел хәлгә тарыгандай пошаманда иде.

Алемасов сәерсенүле карашын машина тәрәзәсеннән алмыйча шактый барды. Аның җанын нидер талкый, изә кебек. Шушы халәтенә җавап тапмый иде ул, югыйсә әле берничә минут элек кенә барысы да әйбәт, барысы да тәртиптә иде бит. Иртәсе дә башка көннәрдәгедән әллә ни аерылып тормый. Көз белән кыш алышынган мәлләргә хас гадәти салкынча иртә. Кәефне исә җен алыштырдымыни — кисәк кенә кара болыт сарды күңел күген. Каты авырудан айный алмый җәфаланучы бетәшкән карт та болай ук яшәү тәмен җуймас.

Кремльгә җитәрәк, Спасс манарасы янындагы капка төбендә сакчылар шәйләнә башлагач, шоферына күз дә салмый, кисәк кенә:

— Туктат әле машинаны! — диде, аннан тирәннән кубарылган төксе тавыш белән өстәп куйды: — Җәяүләп кенә барам...

Шоферның маңгаена салкын тир бәреп чыкты. Кая бара, ни өчен җәяүгә күчте?.. Алай аның шоферлык эшенә телтеш тигезерлек түгел сыман, хафаланырга урын юк та кебек. Шулай да тынычлыкны бозды хуҗаның бу кыланышы. Баш миен бораулап, сораулар кайнашты. Аңа нишләргә хәзер? Хуҗа артына тагылып барыргамы, әллә, аны узып, өлкә комитеты ягына җилдерергәме, әллә соң шушы туктаган җирдә бераз көтеп торыргамы? Тегеләй дә, болай да килешеп бетмәс, ахрысы. Ни булса — шул, сабыр итәргә, көтеп торырга

кирәк тә, хуҗадан йөз-йөз илле адым калыбрак алга шуышырга булыр.

Җәяүләп китәргә ашкынган Алемасов исә алга атларга ашыкмады. Дуамалрак кыланып кабинадан сикереп төште, шапылдатып ишекне ябып куйды. Моңарчы аның үз кулы белән ишек япканы юк иде кебек. Нәрсәгә холыксызлана хуҗа, нәрсә ярамады? Ир уртасына җитсә дә, яшьләрчә шома йөзле, шактый сөйкемле күренгән шоферның тәненә янә тараканнар йөгереште.

Хуҗа, җиргә төшкәч, ике-өч адым атлады да, кемдер озын көн пәлтәсенең чабуыннан эләктергәндәй, шып туктап калды. Шушы мәлдә аңа ышаныч кайтты, ул беренче мәртәбә күргән шикелле Казан урамына, тирә-юньдә караеп торган йортларга күз салды. Күпчелек тәрәзләрдән сүрән ут саркый, шушы утлар урамга аз булса да җанлылык өсти; ниндидер шәүләләр күзгә чалына, — эшкә, белем эстәргә, сәфәргә җыенып вокзалга, тагын кайларгадыр ашыгучы күшеккән бәндәләрне үчекләгәндәй, урамны ду китереп җил йөгереп үтте.

Алемасов тәмам тынычланды. Кыяфәтенә тәкәбберлек иңде, ни өчен болай төшенкелеккә бирелүен аңламаса да, үзенең шушы җирдә нык басып торуына куангандай, һавалы йөз белән янә тирә-якка күз ташлады. Итеге белән аяк астын капшап алды. Нык, бик нык басып тора ул бу җиргә, шушы чуерташ җәелгән урын убылып, каядыр аска очарга тиешле кеше түгел Алемасов, ул үз биеклеген, дәрәҗәсен, мөмкинлеген чамалап эш йөртүче үтә сак адәм. Ә бит имешмимешкә караганда, Казанда җир асты тоташ дип әйтерлек урау-чурау юллардан тора икән. Теләсә кайда, теләсә кайчан аска мәтәлүең бар. Моны аңа Николай Ежов Казанга китеп барыр алдыннан әйткән иде, ничектер кисәткән сыман, сүзләренә күп төсмер салган мәгънәдә. Әйе, уйларга, һәр адымны исәпләп атларга кирәк бу калада! Иң сәер ялкаулык — уйларга ирену, башка ишелгән күп бәлаләр шуның аркасында. Уйларга иренгән кешенең яшәве төссез була.

Уйласаң, уй җитәрлек анысы. Нигәдер моңарчы үз язмышы, тормышы хакындагы уйлардан качарга тели иде ул. Бүгенге иртәдә әнә шул күңел төбендә кузгалмый яткан хисләр кубарылды, җаны шуңа тынгысызланды бугай. Болай җебеп калу, хәтта ун минутлык кына булса да, һич ярамый. Алемасов беркемгә дә ышанмый Казанда, үзен дошманнар камалышындагы бер кеше сыман хис иткән чаклары да күп була. Тик бу хакта беркем дә белергә тиеш түгел, хәтта ки якын күреп йөргән кешеләргә тулысынча түгел, өлешчә дә чишелергә ярамый. Дус дип йөргән кешең ун дошманнан куркынычрак. Казан — ул Казан! Беркемне дә аямый, бер-

кемне дә кызганмый торган, дөньясына, иленә ачулы, үчлекле шәһәр; Казан диварларына бәрелеп, күпләрнең мөгезләре сынды инде. Әмма Алемасов Казанны алачак, дошманнарны сытып-изеп узачак, аның бу шәһәрдәге язмышы бәхетле булачак. Ул Казанга шундый ышаныч белән килде, шундый ышаныч белән эшкә кереште һәм бу, хәтта әйтергә ярыйдыр, сәер ышаныч әлегә аны алдамый иде. Бөтен сәерлек шунда: аның ышанычы фәкать үз-үзенә ныклы ышанычка корылган иде. Кемгә дә булса ул ышанмый да, ышана да алмый, башкаларга исәп тә тотып яшәми.

Казанга килеп оттымы, оттырдымы ул? Каядыр эшкә билгеләнү, шул нигездә каядыр килеп урнашу, кайдандыр китеп бару мәсьәләләре аның үзенә генә бәйле түгел, әлбәттә. Кузбасста, Томскида, аннан Украинаның Кирмәнчек калаларында фирка эшендә чарланган, каты куллы, дошманнарга аяусыз утыз биш яшьлек ир-егет ул. Әле яшь-яшь килеш, егерме бише тулыр-тулмас җитәкчелек эшенә керешеп, ун ел дәвамында абруена тап төшерер бер гамәл дә кылмады, фирка алдында йөзе ак. Ежов аңа Татреспубликаның НКВД халык комиссары вазифасын тәкъдим иткәч тә, риза булмасын сиздереп, кискен каршы төшсә, баш тартса, аның белән кабат сөйләшеп торырлар идеме Үзәк Комитетта? Моңа кадәр, турысын әйткәндә, инде хәзер үзләре дә «дошман» буларак юк ителсәләр дә, Татарстан НКВДсын нык куллы комиссарлар җитәкләгән. Күзгә күренерлек эшләре бар. Өлкә комитетын җитәкләгән Хатаевич, Разумовлар да дошманнар белән көрәшне сүздә генә калдырмаганнар. Оеткы әйбәт салынган. Ләкин көрәшне тагын да кискенләштерергә, Татарстанны дер селкетерлек бер «эш» оештырырга кирәк иде һәм моның өчен кармавычка өлкә комитеты беренче сәркатибе постында шактый эш күрсәтергә өлгергән, башкала алдында абруе тотрыклы күтәрелә барган Лепаны эләктерүдән башка чара юк иде. Алемасов күреп торды — Альфред Лепа, Казанга Ежовның иң ышанычлы кешеләренең берсе килүен чамалап, баштагы көннәрдә югалып та калган сыман иде, аннан үзен кулга алып, Алемасов белән мәчеле-тычканлы уйнарга да маташты маташуын, әмма үзе өчен тыныч көннәрнең бетүен танып, хастаханә юлларын таптарга кереште, партия-совет эшендә алсыз-ялсыз эшләп, өч тиенлек тә сәламәтлеге калмаган, имеш. Болай гына котылып булмасын аңлагач, Алемасов белән ачыктан-ачык сөйләшергә дә омтылды. НКВД халык комиссары аны ярты сүздә бүлдерде:

— Әгәр Совет илендә бармак белән санарлык ышанычлы өлкә комитеты җитәкчеләре бар икән, аның берсе — Альфред Лепа! — диде ул, Беренченең күзләренә туп-туры карап. — Шуңа күрә һич хафаланасы түгел, матур барган эшегезне

дәвам итегез, без исә Сезгә һәрьяклап булышлык күрсәтербез, безләрне Үзәк Комитеттан шуның өчен җибәрделәр дә бит инде.

Лепаның күзләре дымланды бу сүзләрне ишеткәч, әмма күңеле урынына барыбер утырып җитмәде һәм башка тәрәкләр эзләвен дәвам итте, тик өлгермәде...

...Алемасов үзе Казанга килеп төшкән пыскак яңгырлы җәйге көнне яхшы хәтерли. Шунда ук, каршы алырга килгән НКВД хезмәткәрләренең берсе озатуында, өлкә комитетына, Альфред Лепа янына юл тотты. Беренче янына керергә чират көтеп торучылар шактый булса да, аны тиз үткәреп җибәрделәр, күрәсең, Беренчегә алдан кисәтеп куйганнардыр, тегесе исә «кунакның» килеп җитүен түземсезлек белән көтеп торгандыр. Алемасов, бүлмәгә үтеп, берничә адым атлауга, туктап калды. Юк, бүлмәнең шактый зур булуыннан да, зәвык белән җиһазланган булуына да шаккатмады ул, моның ише генә кабинетларны күп күрде, аны кабинет хуҗасы кызыксындыра иде. Ул очлы күз карашын озын өстәл артында тарала төшеп утырган Лепага төбәп, юри шулай аптыраулы халәттә катып калган булды. Шушы ике-өч секунд вакыт җитте, — Лепаның үз-үзенә шулай ук нык ышанган булуын тойды яңа НКВД башлыгы, әмма киеренкелектән Беренченең озынча саргылт яңагындагы мускулларның уйнаклавын да абайлады. Димәк, шикләнә, димәк ки, астыртын көрәшергә өметләнә һәм, күренеп тора, тиз генә бирешмәячәк бу карт төлке. Карт төлке димәктән, Алемасовтан бары биш-алты яшькә генә зуррак Альфред Карлович шактый өлкән күренә. Тар кысалы күзлек кигән, чәченә чал йөгергән, төз борын астында, җирән булса да, үзенә ятышып торган килешле мыек, кысылган иреннәр. Фирка яклавына өмет итүе, авыр чакларда аңа таянырга исәпләве урынлы — Ригада хаккый һөнәр мәктәбендә укып йөргәндә, ат биржасы хуҗасы малае булуына карамастан, яшьтән революция эшенә керешеп китә, 1914 елда ук, бөтендөнья сугышына каршы гамәлләре өчен кулга алынып, Себергә сөргенгә озатыла, кача, тотылгач, төрмәгә тыгып куялар. Революциядән соң Уралда фирка эшендә, гражданнар сугышында Дутовка, Колчакка каршы сугыша. Кыскасы, чыннан да, утны-суны кичкән кеше иде ул һәм аңа каршы көрәштә сак, хәйләкәр булу кирәклеген тиз төшенде Алемасов.

Лепа НКВД комиссарын каршыларга үзенчә ярыйсы әзерләнгән иде: хәтта, тактик адым ясарга маташып, Алемасовның озын бүлмә аша үтеп, өстәл турысына килеп җитүен күн урындыгына шулай ята төшебрәк көтеп алмакчы иде дә, каршысында нык бәдәнле, итләч иренле, шома йөзе кояшта янган, кырыс карашлы, гәүдәгә үзеннән һич калышмаган һәм

шул ук вакытта ыспай киенгән Мәскәү «кунагы» пәйда булгач, сизмәстән урыныннан сикереп торды, өстенә кигән хәрби тукымадан тегелгән яңа кәчтүненең түшенә тагылган гражданнар сугышында бирелгән орденын калкыта төшеп, колачын җәеп, ана таба китте. Нигәдер Лепа уң якка салулап, алга иелә төшеп атлый иде... Кул биреп күрешкәндә, Лепа тоеп алды — Алемасов каты куллы, бер тотса, ычкынырмын димә... Каберең якын булмасын моның ише НКВД комиссары белән.

Тыштан караганда җылы, бик җылы каршыладылар аны Казанда. Әмма Лепа белән беренче очрашуда ук каһәр суккан «кем-кемне» дигән сорау ике арага Зөлкарнәй кылычыдай кереп ятты. Кереп ятты дию генә дөрес булмас, үткеннән, үткен кылыч аларның икесенә дә бертигез янап, баш очларында асылынып тора башлады. Алемасов өчен барысы да шома гына барды дип булмый, вакыты-вакыты белән кылыч аның баш очында да эленеп торгалады, бигрәк тә Лепа үзенең капкынга эләгүгә баруын тойган беренче мәлләрдә шулай булды. Беренченең Мәскәүдәге танышлары, сугышчан дуслары аша Ежовка, Үзәк Комитеттагы җаваплы работникларга чыгарга омтылыш ясарга маташуларын белеп торды НКВД комиссары, аның үзен дошман ясап, «фаш» итәргә азаплана иде Лепа. Әмма Ежов үзе җибәргән кадрга җилләнгыр тигезмәде.

Кылыч җәй азакларында тулаем Лепа өстендә асылынып тора башлады. Беренче, тәҗрибәле җитәкче, эшнең кая таба барганын сизеп, капкынга эләккән киек шикелле бәргәләнде, тик кылыч күзгә күренмәс җептән ычкынып, латыш егетенең киләчәге шактый матур күренгән язмыш юлын сиздерми-нитми кисеп үтте. Лепа Казан белән хушлашмыйча аерылышты, кире кайтырына өмете бөтенләй үк киселеп бетмәгән иде бугай. Тик киткәннәрнең кире кайта торган, киләп сарып йөрү заманнары үткән иде инде. Кайтуын болай кайтты, әмма башкача... Ул Мәскәүгә барып, Сталинның үзенә керергә ирешмәктә җан-фәрман тырышлыклар куйса да, даһи юлбашчы аның ише пешкалар белән вакланып торуга шулай ук күптән нокта куйган иде инде. Андыйлар бер Альфред Лепа гына булса ярый да бит. Мәскәү тарафына хаклык эзләп күпләр китә тора, «хаклык»ны чыннан да тиз табып бирәләр анда. НКВД камераларында берничә көн изалангач, хаклык хакында уйларга да курка башлый адәм баласы... Мәскәүнең гаделлеге башка аның.

Иртәнге йокыдан теләр-теләмәс уянып азапланган Казан урамына ничектер борынын җыера төшеп карап торды Алемасов. Кремль ягына борылды. Шушы мәгъруր кальганы

татарлар төзегән дип лаф оралар бит, ачуың да бер килмәгәе. Имеш, Астрахань, Тубыл, Мәскәү, Бөек Новгород һәм башка шәһәрләрдәге кальгаларны да Казан осталары өешкән. Әйе, татарлар тарих ясарга яраталар, тарихлы буласылары килә боларның, үзләрен цивилизацияле халык итеп танытмакчылар, моны һәрдаим сиздереп торалар, әлеге карашларны үҗәт татарның аңыннан ныклап, яңадан искә килмәслек итеп кысып, сыгып чыгарасы бар. Ул башын гаярь рәвештә югары чөеп катып калды. Тарихны ясарбыз анысы, әмма аны Алемасов теләгәнчә, Үзәк Комитет установкасына туры китереп ясау мәслихәт булачак. Татарда күп үрчегән тарихчылар, менә аларын инде чүплеккә себереп түгәргә вакыт җитте. Ул вәкарь рәвештә тора бирде, ни өчен шулай кылчыклана — моның сәбәбен ул үзе дә аңлата алмый иде әле. Их, шушы урында һәйкәл булып калкып чыгарга иде! Аның күңеле кымырҗып алды. Дәүләт, диләр татарлар, дәүләт кирәк аларга, димәк ки, патша да кирәк. Шәп нәрсә икән ул патша булулары, акылга сыймаслык хәл, ул — Алемасов Александр Михайлович — көннәрдән бер көнне тулы бер республикага патша булды да куйды, моны язмышның тантанасы дими ни дисең?.. Аның йөзенә елмаю җәелде. Күптәннән бирле үзе турында уйланып, хисләнеп алганы юк иде. Бүген иртә шушындый каршылыклы җилкенүдән башланды. Хәерле булсын.

Шулай да яктылык җитми Казанга, җитми яктылык! Ничек җитсен ди инде — ничә еллар корткычлар тырнагында тартыша кала. Милләтчеләрнең бөтен төрләрен, оппортунистларның һәр төстәгесен үрчетеп яткан бит ул үз казанында. Исеме җисеменә туры килә бу яктан караганда. Ә менә тарих мәсьәләсенә килгәндә...

Казанга юлга чыгып китәр алдыннан, Ежов аны кат-кат кисәтте: бүре базы буш булмас, тезгенне азга гына да бушатма, диде. Гаярь җайдак хәлендә булсаң да, кистәнең кулыңнан төшсә, аны иелеп алырга форсат калмаска да мөмкин, дип, бераз шүрләтеп тә куйды. Ул шулай бизәкләп сөйләргә ярата. Юкка гына Хөтбәче Колька дип йөртмәгәннәр аны Казанда. Кулыннан китап төшмәгәнгә, теләндә гел китап сүзе булганга ябышып калган исем ул. Сталин янында булып, Татреспубликага НКВД халык комиссары булып раслангач, Ежов Алемасовны кабат үз бүлмәсенә дәште, тиз генә үз яныннан чыгарып җибәрмичә, аталарча киңәшләрен тезде генә. «Сезнең халыкның бер кимчелеге бар — укырга иренәсез,— диде тимер куллы нарком, көяз рәвештә кабинеты буйлап йөреп. Кылтаеп диярлек, сыңар кулын ялтырап торган бил каешына тыгып, каршысына килеп басты, үзе өчен махсус тегелгән шәп хром итегенең биек үкчәсенә күтәрелә

төшеп дәвам итте.— Укырга кирәк булачак, кадерлем, Казан наданнар шәһәре түгел. Патша галиҗәнаплары тәүге университетларның берсен тикмәгә Казанга китереп утыртмаган. Бер хикмәте бар моның. Казанның тарихын бел, татарның холкын өйрән, шунсыз Казанны алу кыен булачак.— Мин сөйләгәнгә колак сала микән дигәндәй, беркавым тын торды. Алемасовның керфек тә кагарга кыеп аны тыңлавына инангач, ирененә канәгать елмаю кунды.— Казан урамнарының һәр ташы — тарих ярчыгы. Кемнәр-кемнәр, әмма татарлар үз тарихларын яхшы беләләр. Каннарында ул тарих аларның, без белмәгән, белгән кадәресен дәшми торган, онытылырга тиешле тарих! Ә тарих исән, тарих яши... Безнең өчен бик куркыныч бу хәл. Күрәкараучылык НКВД эшендә гафу ителмәслек нәрсә. Бу хакта сиңа кадәр эшләгән иптәшләргә дә,— «иптәшләр» дигәч, төртелеп калды, кисәк читкә атлады, күзен чепиләндереп, каршысындагы кешегә караш ташлады, йөзе агарып чыкты.— Аларның «халык дошманнары» буларак фаш ителүенә бишбылтыр, сабак өчен әйтүем...— Шул чагында Ежовның гаять куркак бер бәндә икәнен сизде Алемасов. Бөтен кыланмышы, көязлеге шушы куркаклыгына ширма иде бугай.— Әйе, мин ул хәшәрәтләргә аз тәкрарламадым, татарлар хәтерле, хәтәр халык, дидем, тик алтындай сүзләргә колак салучы гына булмады. Шул наданлыклары аркасында, бәлки, үзләре дә сизмәстән, дошманнар тегермәненә су коя башладылар. Этне ияртсәң — сукма, кадрларны кая гына җибәрсәм дә, якларга тырышам. Мәскәүдән торып, төбәктә сезнең кыланганнар өчен җавап тоту җиңел түгел. Ышанам, моннан соң Казан ягыннан яман хәбәрләр килүдән туктар. Дошманнарны фаш итүдә безнең тарафтан бернинди дә чикләү юк. Эрерәк кошларны каптырырга тырыш. Корт анасын тотып умартага кертеп япсаң, бөтен күч аның артыннан ояга кереп тула. — Ежовның күзе тоныкланып калды.— Төбәкләрдә эшнең очы-кырые күренми, кемгә карама — сату, кемгә бакма — сатылу. Урындагы түрәләрнең наданлыгы, күрәкарау, дусны дошманнан аера белмәү — шул харап итә Совет илен. Кабатлап әйтәм, синең өчен Татреспубликада буй җитмәслек кеше юк. Обстановкага карап хәрәкәт ит. Билгеле, аеруча мөһим моментларны безнең белән килештереп. Әйтик, мәсьәлә Лепага килеп кагылды ди... Ул латыш миңа нигәдер ошамый...»

Ежов белән булган шушы очрашу, тимер наркомның киңәшләре баштарак Алемасовка тынгылык бирмәде. Лепаның язмышы хәл ителгән дип санарга була, монысы өчен баш ватасы юк, ә менә наданлыкны ничек җиңәргә? Яңа урынга авыр ияләшә ул. Болай да сак кеше, баштагы мәлләрдә кеше белән бөтенләй аралашмый иде диярлек. Ә монда алай эш-

ләргә мөмкин түгел, Мәскәү икенче көнне үк хисап сорый башлады. Күпме дошман кулга алынган, күпмесенә эш кузгатыла, шуларның күпмесенә — атылу... Бу саннар разнарядканың ничә процентын тәшкил итә, дошманны фаш итү планы ни өчен үтәлеп җитми, сәбәпләрен аңлатыгыз... Менә шушы халәттә тарих укып ятып буламы? Сорау алуларда үзе турыдан-туры катнашып, хәшәрәтләрнең телен чишterүдә үз алымнарын (бигрәк тә тотакның башына кыршау кигереп кысу, җенес әгъзаларын келәшчә белән сыту, кумаклы базга төшерү «нәтиҗәле» булды) куллана башлагач кына, Мәскәү алдында йөзе яктыра төште. Кәефе күтәрелгәч бер көнне ярдәмчесе аша Казан тарихына багышланган китаплар соратып алды. Әүвәл Гайнетдин Әхмәров, Газиз Гобәйдуллин, Һади Атласи, татарларның үз арасыннан чыккан бүтән галимнәрнең китапларын, урысчага тәрҗемә кылынган мәкаләләрен укып матавыкланды. Җанына ятышлы эш түгел иде бу. Татар тарихын өйрәнүгә караганда, берәр тотакның теле чишелерлек «хәлгә китерү» мең мәртәбә саваплы һәм канәгатьлек хисе бирер иде. Татарлар үз кавемен ничек тә купайтырга, зур тарихлы итеп күрсәтергә омтылалар. Дәүләтле халык булганнар, янәсе, шәһәр культурасына нигез салганнар, мәгърифәткә ия, имеш, алар. Ачуы килеп, өстәлендә яткан бар китапны җыеп, чүп савытына томырды. Янә, вакыт табып, Карл Фуксның казан татарлары турындагы хезмәтләрен караштыра башлады. Бусы да ошамады. Немец нәрсә дип Казанны, татарны күтәрергә тырышкан — акылга сыймый. Аныңча, татарлар затлы, белемле, тәрбияле кавем. Юк, тарихны инонародецлар язганнар аша түгел, урыслар теркәп калдырганнар буенча өйрәнү муафыйк булыр. Алар инде халык аңын саташтырырлык нәмәрсәләр язып куймаслар. Кул астындагы «Казан ханлыгы тарихы буенча очерклар» дигән китапны укый башлагач, бөтенләй шартлар чиккә җитте, атна буе җенләнеп йөрде. Михаил Худяков, чеп-чи урыс кешесе язган иде ул китапны. Ничекләр кулы күтәрелгән болай язарга?.. Һәм ни хакы бар — бер генә сүзенә дә ышанырлык түгел бит моның. Әгәр дә монда язылганнар дөрес булса... Уйлап кына кара — тарихчы үзенең сүзен «Казан ханлыгының чәчәк атуы» дип башлый. Дәүләтле, мәгърифәтле халыкны урыслар гына харап иткән икән. Баксаң, урыс князьләре, хәтта Дмитрий Донскойның варисләры да, тәхет өчен бәхәскә килеп терәлгәч, артык даулашмыйча, Казан ханы Олуг Мөхәммәткә баш иеп килгәннәр икән. Хәл итеп бир, атакай, янәсе. Тегесе, вәкарь генә боларны тыңлап, мәсьәләне гадел итеп хәл итеп тә биргән. Каршы килүче юк, сүз куертучы юк, бүре дә тук, сарык та исән, берсенең башыннан ник бер чәч өзелсен. Барысы да риза,

барысы да рәхмәт укый Олуг Мөхәмммәткә. Вәт заманнар булган икән, анаңны оргыры. Ул гынамы, Мәскәү патшасы Василий Казан ханында әсирлектә яткан икән, көч-хәл белән үзен акчага сатып алып, кире Мәскәүгә кайтарганнар. Анысы да Казан ханына рәхмәт укып йөргән ди. Бер җүнле ханнары булган, Шаһгали исемле, анысы күңеленә ошады Алемасовның. Һушлы кеше булган, Явыз Иван ягына чыгып, кыйраткан гына Мәскәүгә каршы төшәргә маташкан карулы татарның акыллы башларын. Чыккан бит шушы китап басылып. Укыган бит шуны халык. Урысы да укыган, татары да. Һм... мондый тарихлар әвәләп чыгара башласаң, татар кайчандыр югалткан дәүләтчелеген кире кайтару хыялыннан мәңге ваз кичмәячәк. Юкны югалтып булмый, барны юк итү җиңел. Югалтканны эзләп йөрү — мәзәк тә, гыйбрәт тә. Әнә НКВД подвалында яткан һәр татар милләтчесенең «эше» «Бөек Туран дәүләте» дигән коточкыч сүзләр белән башлана. Инде яшәрлеге калмаганын аңлаганнары, чын-чынлап шушы хыялның дөреслеген раслап, фәлсәфә саталар. Ну мәкерле халык, ә?.. Урысны баскынчылар диюдән дә тартынмаучылары бар. Кем диген инде, үлем ягасына килеп терәлгән, имгәнеп, сытылып, изелеп беткән әрвахлар шулай сөйләнеп азаплана бит.

Ул үзенең урынбасары Михайловка тиз арада Худяков дигән галим кисәген табып, каршысына китереп бастырырга кушты. Ежов хаклы булган, укуның зыяны тими икән кайбер чакта. Худяков бүгенге көндә илнең кайсы почмагында яшәсә дә, аның урыны Казан, «Черек күл» подвалы. Татарның астына җитмешкә бөгәрләнеп кереп яткан бит, мөртәт. Сеңерен сеңергә аерып, ботарлап бетерәчәк аны Алемасов, үз куллары белән ярачак, әмма язганнарыннан ваз кичтерми, тәүбә иттермичә калмаячак. «Урыс Шаһгалие»,— диде ул, тешләрен шыгырдатып, Худяков дигән тарихчының аяк астында аунап ятуын күз алдына китереп, йөзенә кызыл тимгелләр бәреп чыкты. Ләкин аның куанычы кыска гомерле булды, Худяковны, Ленинградта үткән ел кулга алып, «халык дошманы» буларак, тиз арада хөкем итеп, теге дөньяга озатканнар иде. Ә бит андагы чекистлар ашыкмаса, Алемасов Мәскәүнең һушын китәрерлек бер эш оештыра иде. Хәер, Питер берчакта да Казан белән санлашмый инде, хәтта монда хәбәр дә итеп тормаганнар, ахры. Хәлбуки андый кәгазьнең Алемасов кулына килеп кергәне булмады. Шуннан соң тарих укудан бизгән иде бизүен, менә бүгенге иртәдә шул укыганнар искә килеп йөдәтә генә, каһәрең.

Кремльгә карап алуга, башында тарих китапларында укыганнар бөтерелә башлады. Менә ул басып торган җир-

дән Казан ханнары үтеп йөргәндер. Ул көмеш кораллы җайдакларын әйт, ул алар менгән дөлделдәй атларны әйт, ул гаскәрне каршы алырга чыккан кызларның, хатыннарның сылулыгын, гүзәл тыенкылыгын әйт — йөрәкләр иләсләнеп китә болар хакында уйласаң. Атларның корыч дагалары ташларга бәрелеп очкыннар чәчри, урамга чакматашны нәкъ шуның өчен юри җәйгәннәрдер әле! Тояк астыннан ургылып чыгып чәчелгән очкын гаскәрнең куәтен, какшамас рухын күрсәтеп торырга тиеш булгандыр! Булган бит андый дәверләр, булган. Казан дәүләте ни дип сорасалар, ул — гөлгә күмелгән калалар, киекләр уйнаган матур аланлы калын урманнар, балыклар мыжлап торган көмештәй елгалар, тук башаклар чайкалып утырган басу-кырлар иле; бөтен Ауропаны таң калдырырлык таш калалар төзегән осталар, игенчеләр, һөнәрчеләр иле; дөньяның иң бай илләре белән сәүдә итүчеләр, кая барып чыкса да, тылмачсыз аралашкан акыл ияләре иле! Тарихчылар шулай яза. Ничек мондый дәүләтчелекне кайтару турында хыялланмасын башында акылы булган кеше! Мондый дәүләткә хан, патша булу да ярый торган эш, анаңны корт чаккыры. Бүген дә Татреспублика төшеп калганнардан түгел. Хан булмаса да, Алемасовның биләмәсе бу, ул хаким монда, аның рөхсәтеннән башка Татарстан дигән җирдә яфрак та селкенми һәм шушы хакимлек хисе аны ләззәтле кичерешләргә дучар итте, бу хис шундый татлы — рәхәтлектә оета, күңелдәге бая уянып өлгергән авыр ташларны эретә, иңне баскан йөк каядыр тирән бер чоңгылга очты кебек, барысы да әйбәт, һәммәсе шәп, шуны раслагандай бөтерелә-бөтерелә ак кар ява башлады. Казан кары Мәскәүнеке түгел инде, анда әрсезләнеп ярма коела өскә, монда ак канатлы күбәләкләр бөтерелә һавада. Алар талгын гына иңнәргә килеп яталар, сак кына биткә бәрелеп иркәлиләр, керфекләрне сыйпап үтәләр. Әх, яшәү шәп! Менә шулай, татарларым. Түт-тү сезгә дәүләтчелек, түт-тү сезгә тарих! Тарихны сезгә Алемасов үзе китереп тоттырыр, җәме!.. Иң дөрес тарих, иң яңа тарих, тузан кунмаган тапсыз тарих булыр ул, иеме?! Кысыр хыялларны баштан чыгарып атыгыз да эшкә, эшкә, шайтан алгырлары!

Ул, җәяү атларга ниятен онытып, җәһәт кенә машинага кереп утырды...

...Шундый хыялый хисләргә бирелүенә бераз эче пошып, эченнән үзен битәрләп алды Алемасов, кабинетына кереп, кәнәфигә чумгач. Кемдер аның уйларын укып, барысын да язып барган шикелле тоела иде. Бигрәк тә үзен хан урынында күрәсе килү тойгысы тилелек дәрәҗәсендәге нәрсә. Ни дип керә андый уйлар башка! Арудан инде ул, җүнләп ял күрмәгәннән.

* * *

Чыннан да, бирчәеп каткан җанны җылытырлык мәлләр аз булды бу көннәрдә.

Бүгенге иртәдә исә көндәлек мәшәкатьләрдән шадраланып-җөйләнеп беткән җаны хискә бирелеп җепшеде дә куйды. Их, гел менә шундый рәхәт хиссияткә йотылып кына утырасы иде... Шулай уйлап бетермәде, өрфиядәй җиңеләеп, пәрәвездәй тартылып үтә нечкәлек чигенә җиткән нәзберек күңелен яньчеп, сытып, телефон чылтырады. Кабинет хуҗасының йөзенә чиләге белән салкын су бөркеделәрмени — битенә ямьсез тимгелләр йөгерде, карашы каешланды, ниндидер шомлы хәбәр көткәндәй, муенын таушалган кәчтүн эченә җыера төшеп, каударланып трубкага үрелгән иде, кисәк үзенең кемлеген, кайда утырганын исенә китереп булса кирәк, йомшак күн утыргычының артына авып, вәкарь генә каш астыннан киң һәм иркен кабинетын айкап алды. Аннан тәмам үз халәтенә кайтып, иртә таңнан телефон чылтыравын туры үзенә юллаган, шул сәбәпле татлы уеннан бүлдергән ахмак сәркатибенә җен ачуы чыгып, инде яртылаш трубкага үрелгән кулын кискен хәрәкәт белән читкә селтәп җибәрде. Бармак очы тиеп, җай яткан трубка аппарат өстеннән чак очып төшмәде — сәер шыңгырдау авазы чыгарып кире үз урынына кунды. Газаплы аваз кебек тоелды аңа әлеге сулкылдаган тавыш, ни сәбәптер күңеленә рәхәтлек таралды. Шулай да сәркатибенә кабынган ачуы сүрелмәде.

Кабинетына керә-керешкә үк йокысыннан айныр-айнымас утырган сәркатипкә: «Мин юк!..» дигән иде бит инде. Нәрсә җитми тагын? Бу сүзләрнең ни-нәрсә аңлатканын белмиме сөрхәнтәй?! Ул бар, әмма ул юк. Татарлар әйтмешли, Хозыр Ильяс кебек, ягъни... Исең китәр өлкә комитетында эшләүче бу татар түрәчекләренә. Бер сүз сөйли башласалар, һичшиксез, мәдрәсәдә укыган дини китапларыннан мисал китереп, сүзләренең асыл максатын ассызыклап кыланган булалар. Имеш, алар буш сүз сөйләми, борынгыдан килгән акылга таянып фикер йөртәләр. Имеш... Төптән уйлап эш йөртә татарлар, һәр сөйләшүдән соң үзенең, аларга карагандa, һәм белем ягыннан сайлыгын чамалап, һәм тормыш итү тәҗрибәсенең җитенкерәмәвен сизеп, котырыр чикләргә килеп терәлгән вакытлары аз булмый.— Ишәк...— диде ул теш арасыннан, ярсуын тыя алмыйча янә сәркатипкә ябырылды.— Бүген үк артына тибәргә кирәк бу агач бүкәннең.

Ял итәргә вакыт юк инде анысы. Шулай да җаны теләгәнчә итеп гомер үткәрүләр булмый түгел. Менә үткән төнне дә нинди матур сәхифә язылды аның гамәл дәфтәренә! Ширә булмаса, нишләр иде ул, ә? Бөтен борчуы, җанын талкыган көндәлек мәшәкать, кысыр хәсрәтләрдән шушы бө-

терчек кызый гына аралап ала бит. Аны уйласа, шундук тәне кызыша башлый. Фәкать мәхәббәт, сөю, сәгадәт өчен генә яратылган бу кызыйны дистәләгән чибәрләр арасыннан сайлап, үзенеке итә алуына бик тә канәгать иде ул. Сөешү мәсьәләсендә татар кызларына җитми икән! Ул татлы киерелеп куйды. Үзләре куркак, үзләре йомшак, хисләре кабынып китсә дә, акылларын югалтып бетермиләр. Инде хатын-кыз затын күрмәде түгел, күрде, әмма Ширә башка инде! Кайчандыр үзенең күңеленә кереп калган кыз-кыркыннарны шушы татар кызыкае белән чагыштырып карый да башын чайкап куя. Җир белән күк арасы. Тегеләр соң, бераз үзләшеп кенә алсыннар, минуты белән барлык чикләрне җимереп ыргыталар. Ихахайлап өстеңә ташланучы, оятсызларча шашынучы, хайвани дәрт белән бәргәләнүче сары чәчле Наташа, Марья, Ниночкалардан шушы татар кызының тыйнак яратуы мең мәртәбә артык шул. Шуңа күрә Разумов Татарстаннан бик авыр кубарылгандыр да. Китәргә теләмичә, шактый карышып маташкан, диләр бит.

Татарлар һәрьякка да булган халык икәнен республикага эчке эшләр халык комиссары итеп җибәрелгәнче үк ишетеп белә иде, инде менә үз күзләре белән күрде, тәне белән дә татып карады.

Ширәне ул җәй көне, комсомол өлкә комитетында үткән бер җыелышта күрде. Кайсыдыр заводтан комсомол активисткасы буларак чыгыш ясауны аңа тапшырганнар иде. Кыз трибуна артына каушап чыкса да, кәгазьгә карамыйча диярлек, әйтәсе килгәннәрен җиренә җиткереп сөйләп чыга алды. Чыгышны әзерләүчеләр нык тырышканнар, кыз социализм төзүгә комачаулык итүче «халык дошманнары»н, урындагы пошмас җитәкчеләрнең тетмәсен тетеп ташлады. Кызның төс-кыяфәтен күрүгә үк президиумда утырган Алемасов, сизмәстән, чыгыш ясаучының исем-фамилиясен алдындагы кесә дәфтәренә теркәп тә куйган икән. Хәбипова Ширә, эшче-комсомолка, яшь стахановчы.

Җыелыш бетүгә, өлкә комитеты секретаре Мөхәммәтҗановны эзләтеп таптырды һәм, икеле-микеле сөйләшүгә юл калдырмыйча, кызга чыгышны кем язып биргәнен белешергә кушты. Мөхәммәтҗанов, гомер булмаганча, ни сәбәптәндер бер мәлгә югалып калды, бераз уйланып торганнан соң, ныгый төшеп:

— Чыгышны кем язганын әйтә алмыйм, әмма тезисларын эшләүне Дәүләтъяровка тапшырган идек,— дип ярып салды.

Алемасов сизенде, Мөхәммәтҗанов шомарып баручы партия работнигы, югары даирәдә уеннарның ничек оештырылганын яхшы аңлый, республикада үз позициясен ныгыту ягын да кайгырта килә — тирәсенә белемле, тынгысыз, әмма сүз-

дән чыкмый торган яшь кадрларны туплый. Татреспубликада егетнең абруе көнләп түгел, сәгатьләп үскән чаклары да булган. Моны Алемасов яхшы белә, ник дисәң, Лепаны Татарстан өлкә комитетыннан алып ыргыткач, Мәскәүдә Мөхәммәтҗанов кандидатурасына тукталырга да уйлаганнар берара. Моны Алемасовка Маленков сер итеп әйтте. ҮК утырышында политбюро әгъзаларыннан кайсыдыр Мөхәммәтҗанов фамилиясен ычкындырган, имеш... Әмма Сталин орлыкны кибәктән яхшы аера. «Татарстанда өлкә комитетының беренче секретаре һәм эчке эшләр халык комиссары булырлык милли кадрлар үсеп җитмәде әле»,— дигән ул, бу фикерне ишетүгә кырт кисеп.— Совет властеның беренче елларында шушы мәсьәләгә ныклы фирка позициясеннән торып якын килмәгәнгә, авызны пешердек тә бит. Кайбер иптәшләр шушы мөһим нәрсәне оныттылар булса кирәк...— дип, кабат Мөхәммәтҗанов фамилиясен атамаслык иткән.

* * *

Кибәк дисәң дә, кем кем, әмма Мөхәммәтҗанов кибәк баш түгел, Алемасовның чибәр Хәбипова хакында юкка гына сорашмавын чамалый иде. Чыгышына караганда, кызның үзен ошатты бу әрсез Мәскәү әрләне. Шулай ук чыгышы да ошады Алемасовка, киресе булса, яңа түрәнең Хәбипова турында сорашканда йөзе балкып торыр идеме? Мөхәммәтҗанов уенның җеп очы үз кулында икәнен аңлады. Әлеге моментны үз позициясен ныгытуга файдаланып кала алмаса, аннан тавык көләр иде. Шуңа күрә, икеләнмичә, Дәүләтъяров фамилиясен атады. Югыйсә Ширә Хәбипованың үзен дә, өлкә комитетында аның чыгыш ясарга тиешлеген дә соңгы айларда гына «Кызыл Татарстан» газетасының җаваплы редакторы итеп расланган Әхмәтсафа Дәүләтъяров белмәгән дә иде. Әмма форсатны ычкындыру гафу итмәслек хәл иде. Хәбипованы Мөхәммәтҗанов яхшы белә, комсомолка-ударник, чор идеалларына ышанып, үзе кебек бер активист егеткә уңышсыз кияүгә барып кайткан яшь хатын иде. Гаилә тормышы барып чыкмау сәбәпле, язмыш тарафыннан йөрәкләренә яра ясалган яшь хатыннардан хезмәт алдынгысы, җәмәгать эшлеклесе, активистка ясау кулай. Билгеле, мондый типтагы активисткалар үзләреннән ни-нәрсәләр таләп ителгәнен чамалый алырлык акылга да ия иделәр. Хәбипова акыллы кыз иде. Җыелышта Алемасов катнашачагын, инде аның Лепа урынына Беренче секретарь булырга тиешлеген яхшы күзаллаган Мөхәммәтҗанов Хәбипованы бик вакытлы уенга кертеп җибәрде һәм теләгенә иреште дә. Кыз хакында сорауны ишеткәч, аптырап, югалып калу галәмәте

күрсәтүе аның кыланып маташуы гына булса да, моны Алемасов табигый кабул итте.

— Дәүләтъяров?.. — диде Алемасов, күптән көтелгән исемне ишетүенә куанган сыман. — Беләм, Бауман райкомы конференциясендә ясаган чыгышын дикъкать белән укып чыктым, хәзерлекле иптәш күренә...

— Әйе, райком секретаре Разживинга элəкте ул чакта безнең егеттән. — Мөхәммәтҗанов «безнең» сүзенә басым ясап әйтте һәм Беренченең күзенә туры карап алды.

Алемасов Мөхәммәтҗановны аңлады кебек...

## II

Утыз җиденче елның маенда үткән Бауман партия оешмасы конференциясендә ясаган бу чыгышны Мөхәммәтҗанов белән Әхмәров оештырганнар иде. Үзәк Комитет көн саен «халык дошманнары»н фаш итүдә җирле партия органнарының сүлпән эшләвен күрсәтеп торганда, Беренче секретарь Альфред Лепа белән халык комиссарлары советы рәисе Кыям Абрамов әлеге мөһим чараны тормышка ашыруда югалып калдылар шикелле. Дөресен әйткәндә, Лепа белән Абрамов ҮК кубарган вакытлы шаукымга бирелеп, кадрларны харап итмик диебрәк эш йөртергә исәп тоттылар булса кирәк. Мөхәммәтҗановның нияте башкарак иде. Әгәр шушы сәяси кампаниядә үзен күрсәтмәсә, киләчәктә нәрсәгә өмет итә алачак ул? Әйтүе кыен. Шуңа күрә саклык белән генә эшкә кереште. Форсаты да чыгып тора — районнарда конференцияләр башланды. Беренче нәүбәттә иң мәртәбәле саналган райком җитәкчеләренең берсен — Разживинны селкетеп алу начар булмас иде дип уйлады ул һәм ялгышмады. Дәүләтъяровны чакырып ныклап сөйләште. Йоклап калсак, таптап үтәчәкләр безнең өстән, дип тә кисәтте, мисаллар исә җитәрлек иде — кичә генә кул бирешеп, хәл-әхвәлләр сөйләшеп торган дустың саналган кешенең икенче көнне «халык дошманы» булуын ишетеп, өнсез каласың. Башны кибән астына тыгып ятар чак түгел. Акылны эшкә җигеп, һөҗүмгә күчәргә кирәк.

— Җитәкчеләр ниндирәк фикердә? — дип сорады Әхмәтсафа, әңгәмәдәшенең үзен гайре эшкә тартып кертергә чамалавын аңлап.

— Нинди җитәкчеләр? — диде, сорауны аңламаганга сабышып, Мөхәммәтҗанов. Аннан Әхмәтсафаның колагына пышылдады: — Лепа белән Абрамовны әйтсәң, алар инде үтелгән этап. Сәясәт икеләнеп торучыларны яратмый. Әзиләрнең (үзеннән өлкәннәргә дә, яшьрәкләренә дә мишәрчәләп «әзи», ягъни абзый дип эндәшергә ярата иде ул) җырлары

җырланды булса кирәк, шулай сизенәм. Безгә мөстәкыйль хәрәкәт итәргә кирәк, әмма алны-артны бик нык уйлап. Без өчәү — син, мин һәм... Әхмәров... Вакыйгаларны, кирәккәндә, хәрәкәткә китерә алырлык, кирәксә, туктатырлык рычаг безнең кулда булырга тиеш. Шушы юнәлештә эш алып бара башларга вакыт. Калганын Әхмәров белән серләшерсез.— Мөхәммәтҗанов кинәт колак төбенә үк иелде.— Безнең бүгенге сөйләшүне кабергәчә сер итеп сакла!

Чыгышның караламасын әзерләү Әхмәровка йөкләнде. Мөхәммәтҗанов үзенә тиңнәрне сайлауда дөрес юлда иде, Дәүләтъяров моңарчы Минзәлә, Кызыл Йолдыз районнарында эшләп чыныгу алган җитәкче, тормышны яхшы белә, докладта күтәрелгән һәр мәсьәләнең төбенә төшми торып, трибуна артына чыгып басмаячак иде. Оренбур Каргалысында туып, балигъ булган егет белән Чүпрәле районына кергән Татар Бизнәсе авылында туып-үскән Галим Мөхәммәтҗановның серләре килеште. Галим кискенрәк холыклы, дуамалланып, таякны артык бөгеп ташларга ярата, аңа эшнең нәтиҗәсе тиз күренсен, ни гамәл кылса да шауларгарак ярата. Әхмәтсафа исә тыныч, сабыр кеше, кайбер кыенлыкларны уен-көлке белән дә үткәреп җибәрә белә. Галимгә нәкъ менә шундыйрак егет кирәк тә инде. Әхмәтсафага таянырга була. Ул — аспирантурада белем алган, югары уку йортларында студентларга сабак биргән коммунист, сыйнфый көрәштә чыныккан большевик. Бераз киреләнсә дә, ныклап карышыр җае юк. Чөнки Дәүләтъяровны Казанга кайтартуда Галимнең дә өлеше бар.

...ТКУда укыганда танышканнар иде алар. Татарстандагы җитәкче работникларны, белгечләрне берәм-берәм «дошман» ярлыгы тагып чүпли башлагач, кадрларга кытлык килеп туды. Китап нәшриятында сәяси әдәбиятны тәрҗемә итү эше аксый башлады. Бу өлкәдә тәртип урнаштыруны, нәшриятны яшь кадрлар белән ныгытуны өлкә комитеты Мөхәммәтҗановка йөкләде. Тәрҗемә эшендә Әхмәтсафаның азмы-күпме тәҗрибәсе бар, шуны искә алып, Дәүләтъяров белән күзгә-күз карап сөйләшү өчен махсус рәвештә Кызыл Йолдыз районына сәфәр чыкты Галим Мөхәммәтҗанов. Алдан киләсен хәбәр итүен итте, ләкин Дәүләтъяров аны райком бинасында көтеп тормаган булып чыкты. Ул көч-хәл белән басудан эзләп тапты Әхмәтсафаны. Райкомның икенче секретаре кулында тәрәзә рамына охшаган нәмәрсә. Хатын-кызлар урак ура, Дәүләтъяров җитди эш башкарган кыяфәттә, әле бер, әле икенче кишәрлеккә килеп, урылган мәйданга шушы раманы болгап ыргытып җибәрә. Агач рама кайда барып төшсә (аның төгәл күләме — бер квадрат метр иде), шуның эчен җентекләп тикшереп карыйлар, коелып кал-

ган башак юкмы, булса, ничә бөртек? Котлы Бөкәшнең колхоз басуында иде бу хәл һәм ул елларда киң таралган контроль ысул — районнан килгән вәкилләр урак уручы хатынның бер квадрат метр мәйданда башак калдыру-калдырмавын тикшереп йөриләр иде. Сыңар башак табыла калса, шунда ук чарасы да күреләә — уңмаган бичә өенә кайтмый ул көнне, караңгы төшеп, эш тукталгач, колхоз идарәсе базына ябып тотылырга тиеш иде. Шул рәвешле сыйфат өчен көрәш тормышка ашырыла, урактан арып-талып кайткан хатынкайлар, базда бераз «тын алгач», төнгә өстәмә эшкә чыгарылалар. Бер башак өчен — бер төн өстәмә эш, ике башак өчен — ике төнне йокламый эшләргә тиеш, инде башак саны өчкә җитсә, кырда ук аңа суд ясалып, ике-өч ай төрмәгә дә ябылырга мөмкиннәр иде. Бу вакытта бичара хатынның бала-чагасы, гаиләсе нишли — анысын уйлап та тормыйлар иде.

Эссегә чыдар әмәл юк. Яңгырлар озак яумый торып, шактый өлкәләргә ачлык килү куркынычы яный. Украина инде бүгеннән үк чаң суга башлады. Кайберәүләр утыз алтынчы елны егерме беренче елгы ачлык белән дә тиңлиләр. Шуңа күрә әрәм-шәрәм итүләргә каршы кискен көрәш башланды. Котлы Бөкәш басуларында, шөкер, уңыш бөтенләй үк юк түгел. Галим, машинадан төшкәч, балачактан ук калган гадәт буенча, кояш астында әлсерәп утырган нәзек буынлы, кыска башаклы арыш учмасын алып, кулында уып мәшәләнде. Шулай да коры эсселек, нәкъ балавыз чагында китереп сугып, бөртекләрне куырып өлгергән икән. Әкрен җил сабакта нык утырган арышын, бодаен каядыр алып китмәкче булып куалый да куалый. Бу якта басулар иркен, офыкка кадәр таралып яткан кырлар, җилгә карышмыйча, корылыктан котылырга теләп, каядыр еракка талпыналар кебек. Кама яклары эңгергә төренеп, әлеге әлсерәүле халәтне көчәйтеп кенә җибәрәләр.

Дәүләтъяровның үз янына килеп җитүен сабырсызланып көтеп алды комсомолның өлкә комитеты секретаре. Ул Әхмәтсафага караганда өч яшькә кечерәк, әмма үзен аның алдында иркен тота. Ни әйтсәң дә, ВКП(б) өлкә комитеты әгъзасы, аңа өмет баглыйлар, үзе дә сынатмый, ышанычлы рәвештә алга атлый иде.

— Ну килештерәсең дә инде, Дәүләтъяров, нүжәли райкомда гына утырып булмый инде, ә?.. Кичә телефоннан ачык сөйләшкән идек ләбаса!

— Иптәш Вәлиев райком составын тулысынча колхозларга таратты. Мөхәммәтҗановны каршы алырга кирәк, дип әйтеп караган да идем, үзем булам райкомда, диде.

— Анысына рәхмәт, каршы алды, синең янга озатырга

кешесен дә тапты, тик миңа, үзең булсаң, яхшырак буласы иде...

Галим райком секретареның бөтен эшен ташлап, кулына шәкелтмә — агач рама тоткан булып, партия установкасын башка кешеләргә ышанмый, шәхсән үзе генә үтәп йөрүен килештереп бетермәде. Дәүләткүләм мөһимрәк тә эшләр бар бит, мондый пүчтәк нәрсә белән шөгыльләнү өчен аспирантура тәмамлау кирәкми, колхозның үз активистлары беткәнме, ачуың бер килмәгәе. Билгеле, Дәүләтъяров та бу эшкә атлыгып тормый, әмма Вәлиев, райкомның беренче секретаре, Казаннан киләчәк кунаклар алдында нәкъ менә аның агач рама тотып йөрүен таләп иткәч, нишләмәк кирәк? Ул елларда сыйфат мәсьәләсе дигән булып, колхозчыларны җәберләүнең әллә нинди ысулларын, махсус «тәрбия» методлары куллану киң җәелгән иде. Авыл баласы булган Мөхәммәтҗанов моны да өнәмәвен сиздерәсе итте.

— Кыз-хатыннар артына тагылып йөргәнче, колхозларның техник куәтен арттыру турында уйларга кирәк, электрны эшкә җигәргә...

— Уйламаган кая инде, иптәш Мөхәммәтҗанов. Өлгереп буламыни. Җитмәсә, быел бугаздан корылык дигән җаһил эләктереп алды. Әрәм-шәрәм итүдән куркып, булган ургычларны да чыгармадык. Кул белән генә урырга туры килә.

Галим, дәшми генә тыңлый биреп, янә басу эченә атлады. Кызыл Йолдыз районына килүенең максаты басу-кыр эшләре белән генә танышу түгеллеген, сәбәпнең тирәндәрәк булуын Дәүләтъяровка ипләп кенә аңлатырга кирәк иде. Ул республика күләмендә үз урынын ныгытырга омтыла, мондый чакта янында таянырга ныклы дуслар булуы шарт, картлар әйтмешли, этсез куян тотып булмый, дусларны барларга, читтәгеләрен Казанга җыярга, тупларга дип йөргән көннәре. Кәнәфи өчен көрәш гаҗәп нәрсә ул, аяусыз, миһербансыз көрәш, көрәштәшләр кирәк аңа. Искәрткәнчә, Котлы Бөкәшкә нәкъ менә Әхмәтсафаның кылларын тарткалап карау нияте белән килеп төшкән иде һәм ялгышмады.

Дәүләтъяров, Казанга кайту турында сүз кузгалгач, уйланып торды да:

— Шуның өчен генә килдегезме Котлы Бөкәшкә, — дип, Галимгә сынаулы караш ташлады.

— Гаҗәпме?.. Минем тәкъдимне бөтен яктан да исәпләп карасаң, вак-түәк эш артыннан килмәвемне үзең дә төшенерсең, брат.

— Сәяси әдәбиятны тәрҗемә кылу никадәр мөһим эш икәнен яхшы беләм мин, сүзем ул хакта түгел — Казанга кайту минем теләктән генә тормый бит әле. Иң авыр вакытта районны ташлап киттең димәсләрме?

Галимнең коргаксыган иреннәренә елмаю кунды.

— Аптырама, брат, Мөхәммәтҗанов алынган икән, андый сүзләргә тиз заслон куярбыз. Миңа синең фикерне белү кыйммәт иде. Каршылыгың юк икән, бер атнадан юлга җыена башла. Балаларыңа — бакча, хатыныңа эш табылыр.

Әхмәтсафаның йөрәге җилкенеп типте.

— Мин риза...— диде ул, хискә бирелеп. Ни өчен җанында хисләр давылы, бик үк аңлата да алмас иде. Җан тартмаса, кан тарта, диләр. Казанга тартылу да борынгыдан килгән бер теләк, табигый бер хистер инде ул.

Галим Әхмәтсафаны кочаклап алды. Аның исәбе гади — үзен колхоз тормышыннан аралап, Казанга чакырып кайтарткан кешене Әхмәтсафа тиз онытырга тиеш тә түгел. Ул игелеккә игелек белән җавап бирә белә торган инсафлы егет. Моңа Галимнең иманы камил иде һәм соңга таба әлеге исәп тулысынча акланды.

...Әхмәтсафа, Казанга кайтуга, яңа вазифага җиң сызганып кереште. Югалып, җебеп калмады, тирәсенә сәләтле кешеләрне җыя башлады, яңа дуслар тапты. Таттосиздат директоры Әхмәров белән ул чорда аеруча якынаеп киттеләр. Әхмәровны озакламый Мөхәммәтҗанов үз янына, өлкә комитетына алдырды. Инде чират Дәүләтъяровта. Оста оештыручы буларак танылу алган бу акыллы, күндәм егетне Мөхәммәтҗанов мөмкинлек чыккан саен югарырак күтәрә торды. Әхмәров өлкә комитетына күчкәч, Дәүләтъяров Таттосиздат партия оешмасын җитәкли башлады.

Мөхәммәтҗанов Дәүләтъяровның һәртөрле яңалыкларга, шаукымнарга сак каравын яхшы белә. «Халык дошманнары»н фаш итү мәсьәләсенә дә шулай сакчыллык күрсәтә кебек. Галим бер яктан егетнең уйлап эш йөртүен хупласа да, нигездә, Әхмәтсафаның әкрен кыймылдавына эче поша иде. Аны ничек тә алгы позициягә чыгарасы килә, сәләтле кадр итеп танытасы килә. Шунсыз аны тиешле югарылыкка «тартып» менгезеп булмаячак дип саный иде.

Яз көне Таттосиздатта ВКП(б) ҮКның февраль пленумы карарлары буенча җыелыш үткәрелгән иде. Ә карар, ныклап уйласаң, йөрәкләргә шом салырлык, Совет илен тыштан да, эчтән дә дошманнар сырып алган, тыштагы дошманга караганда, эчке дошманнар мең мәртәбә мәкерлерәк тә, куркынычрак та. Шуңа күрә эчке дошманнар белән көрәштә коммунистик ныклык үрнәген иптәш Сталин үзе күрсәтеп бирде. Аның Тухачевский кебек иң явыз корткычларны фаш итә алуы гына да ни тора. Явыз Тухачевский шанлы Кызыл Армиянең алтын баганасы булган кавалериягә ябырылды бит. Әйтергә генә ансат, аның сүзенә алданып, кавалерияне сан ягыннан киметеп, алгы сафка иләмсез, котсыз танк дигән

нәмәрсәне чыгарсаң, илне бөлгенлеккә төшереп, бар көчне шушы тимер шайтанны эшләүгә тартсаң, кая барып чыгар иде Совет иле? Ярый әле Сталин янында Ворошилов, Буденный кебек какшамас рухлы каһарманнар бар, алар Тухачевскийның илне как таякка калдыруга юнәлдерелгән сәясәтен тиз фаш иттеләр. Бер танк йөз атны алыштыра, имеш. Алыштырыр, бар, атны үрчетү өчен чыгым кирәкми дә диярлек, теләсәң, меңләп-меңләп үрчи ул, айгырларың гына чыдасын. Ризык дисәң, печән, салам ягына килгәндә, Рәсәй, шөкер, беркайчан да кытлык кичерми. Көньякта корылык булса, Себер ягында күкрәп үсә печән, Идел буенда уңмаса, Кавказ ягында җитәрлек табып була. Ә танкка кәрәчинен тап, тимер-томырын ясап өлгер. Корткычлар танк эшли торган заводта диверсия ясап ташласалар, шымытыр башын тотып калырсың! Шул рәвешле ҮК пленумы дошманның никадәр мәкерле, астыртын икәнен күп мисаллар белән раслады. Инде урындагы дошман элементларны аяусыз фаш итәргә, идән асты тараканнарын якты дөньяга чыгару эшенә дәррәү күтәрелү кирәк иде.

Өлкә комитеты кушуы буенча, Татгосиздатта да арадагы дошманнарны ачыклау эшенә керештеләр. Тәүге җыелышларның берсенә көн тәртибенә язучы Гомәр Галине тикшерү мәсьәләсе куелды. Җыелыш протоколын үзе алып карады Мөхәммәтҗанов, хәтта ки ныклап өйрәнде, шунысы мәгълүм булды, бу документка карап фикер йөрткәндә, Әхмәтсафаны һич тә югарыга «төртеп» булмый иде әле. Кара инде, дошман тегермәненә су коеп яткан Гомәр Галине вәч-бәрәмәч китереп бетерер иде бераү булса, ә Дәүләтъяров кызган коммунистларны суытып кына утыра. Фактлар җитәрлек, тетмәсен тетә алалар иде Гомәр Галинең. Җыелыш шул рухта башланып та китә әнә.

Коммунистлар турыга яралар.

— Гомәр Гали Такташның «Сайланма әсәрләр»ендәге кереш сүздә Троцкийга уңай бәя бирде, моны иң явыз «халык дошманы» гына эшли ала!..

— 1925 елда Берлинда контр Галимҗан Идриси белән очрашуын искә алыгыз, иптәшләр. Тапкан очрашыр кеше. Нәрсәләр сөйләде микән Гали бу немец шпионына?..

— Кайсы якка китереп басмасын, Гомәр Галинең аяк асты яна. «Халык дошманы» Гыйлемдар Баимбетов белән дус булуы гына да аның «дошман»лык дәрәҗәсен ачык раслый...

Гомәр Галинең хаталары ачылганнан-ачыла, ә Дәүләтъяров ләм-мим.

Бу эштә кемгә таянырга соң? Гомәр Толымбай да Дәү-

ләтъяров кебек саклык күрсәтә. Йә инде, шул да булдымы фаш итү?! Толымбайга сүз бирелгәч:

— Гомәр Гали ялгышларын үзе дә белә, төзәтү җаен да табарга тиеш, — дип, авыз эченнән ботка пешерә дә урынына утыра.

Галинең ялгышларын санап, төзәтү юлларын кем әйтергә тиеш соң? Кызыл профессор сүзләреме бу? Исхак Рәхмәтуллинга рәхмәт, ул бераз кыдрачланып алмаса, җыелыш бөтенләй тешсез үтәр иде.

— Гомәр Гали белән Вәли Шәфигуллин уң группада катнашучылар, — дип күрсәтә ул. — Шәфигуллин үзенең гражданнар сугышындагы заслугаларын пәрдә итеп куймакчы иде. Ярый әле органнар йоклап ятмый, тиз фаш ителде бу корткыч. Мәсьәләгә тагын да ачыклык кертик, Гомәр Галинең «Безнең юл»да Татарстан белән Башкортстанны кушарга кирәк дип язып чыкканын онытмадыгызмы? Даһи Сталинның милли сәясәтен Галичәләп тар-мар итәргә талпыну түгелмени бу пычрак адым? «Халык дошманы» Фатих Сәйфине яклап чыкканын исегезгә төшерегез. Йөрәк өши бит, иптәшләр, йөрәк өши... Мәхмүт Галәүнең әсәрләреннән өзек бастырып чыгарырга маташуы, инде дә килеп 1934 елда «Хисаметдин менла»ны бастырыйк дип шаулап йөргәнен дә хәтерлибез, болар барысы да аның сәяси хаталанучы гына түгел, ә «халык дошманы»на әверелеп баруын күрсәтеп бирүче фактлар.

Дәүләтъяровның йомшаклыгы аркасында тәки җыелыш ныклап Гомәр Галине төзәтү юлына бастырмый, мәсьәләдән читләшә.

— Иптәшләр, фактларны ныклап тикшерми торып, карар кабул итү урынлы булмас... — дип, бу мәсьәләне тикшерүгә нокта куя.

Нур Баянның Фатих Кәримгә каршы авыз ачып сүз әйтүе була, Дәүләтъяров, тегене шып туктатып, мәсьәләне бытовизм сазлыгына кертеп батыра. Имеш, Фатих Кәрим соңгы вакытта гонорарны мул каерган, шуңа кылтая, шуңа инициативасыз йөри. Акчасы беткәч, активлашыр әле, янәсе... Ә бит Фатих Кәрим «халык дошманы» буларак фаш ителеп, эшсез калгач, аңа кесә тутырып гонорар бирүче Дәүләтъяров үзе булып чыккан. Шулай инде, колхоз басуыннан килеп кергән кешене шәһәрдә тамыр җибәргән дошман элементларын тиз генә танырга өйрәтеп булмый торгандыр. Шамил Усманов турында да ныклы сыйнфый позициядә тормый икән. Аны гаепләп бер сүз әйтми. Ныклап уйланырлык фактлар бар — коммунист Җамал торып баса да, җыелыштагыларга:

— Вәли Шәфигуллинның хатыны иренең «халык дошма-

ны» булуына ышанмый, алай гына да түгел, «кулга алынганнарның барысы да гаепле түгел» дип сөйләнеп йөри,— ди.

Шартлау булырга тиеш иде бу сүзләрдән соң. Бу бит соңгы вакытларда колакка чалынып киткәләгән: НКВД бер гаепсез кешеләрне кулга алып, дошман ясый, дигән контр сүзләрнең йөз процентка раслануы. Раслаучы бар, гаеплесе күрсәтелгән, бу фикергә таянып, җыелышның накалын алга үстерүче хет берәү табылганмы? Табыламы соң! Шушы сүзләргә каршы адәм рәтле сүз әйтүче юк, чынлыкта җыелыш, «халык дошманнары»на каршы көрәшне көчәйтәсе урынга, әлеге әһәмиятле чараны үткәрүче партия органнары эшчәнлегенә шик белдергән формада үтә. Менә бит ничек. Әгәр Дәүләтъяров кебекләрне активлаштырмасак, бу вазгыятьтә кемгә таянырга? Шуларны искә тотып, Дәүләтъяровтан кыю-кыю адымнар ясатырга кирәк иде. Ә егет зиһенле, тәҗрибәсе бар, кул астына алып, иренмичә тәрбия итсәң, файдалы кадр булачак.

...Бауман районында үтәчәк конференциядә чыгыш ясарга дигәч, Дәүләтъяров каршы килмәде. Караламаны Әхмәров әзерләгән иде, аны яңадан кат-кат тикшереп чыктылар. Әхмәров бер төнне Әхмәтсафаларның өенә үк килде. Төнгә кадәр һәр сүзне, өтерне тикшереп чыктылар. Кайбер чакта бәхәсләшеп, кызышып та киткәләделәр.

Абдулла Әхмәров яңа гына өлкә комитетының пропаганда бүлеген җитәкли башлаган кеше, Мөхәммәтҗанов алдында һич тә сынатасы килми иде. Шуңа күрә чыгышта саллырак фактлар алынырга, кырыс фразалар тулып ятарга тиеш дип саный. Дәүләтъяров исә йомшаграк тон сайларга маташа.

Ниһаять, чыгыш «тәртә арасына» кергәч, Әхмәров кайтып китте. Әхмәтсафа хатыны янына килеп утырды. Аның йокысы качкан иде.

Рабига йоклап китә алмый ятты, бәхәсләрне ишетеп торды, шуңа күрә җаны тыныч түгел иде. Иренең күңел халәтен аңлап, үзе дә торып утырды.

— Ник йокламыйсың, Рәбуш? — дип, Әхмәтсафа хатынын кочып, күкрәгенә кысты. Рабиганың җылы тәне әллә нинди рәхәтлек бирде.

— Куркам мин, Сафа. Нәрсәдер булыр кебек безнең белән...— Рабига аһылдап иренең күкрәгенә капланды.— Туйдым мин Казаннан, Котлы Бөкәштән кайтмасак...

— Җүләр сүз сөйләмә. Илдә көрәш бара. Аяусыз көрәш... Моннан бер генә кеше дә читтә кала алмый. Котлы Бөкәштәме мин, Базарлы Матактамы, Минзәләдәме, көрәшнең алгы сафында булырга тиешле кеше.

— Кем белән көрәшергә инде? Бөтен танылган язучылар «дошман»га әйләнеп беттеләр.— Рабига балалар Үзәк ки-

тапханәсендә эшли иде.— Кайчан гына Садри Җәләл, Сәйфи-Казанлы китапларын чыгарып яндырган идек, кичә Кави Нәҗмигә чират... Кави Нәҗми — кызыл командир, дип йөрдек. Аны да «дошман» диләр. Ахыры бармы бу эшнең?.. Минем баш җитми моңа.

Әхмәтсафа, хатынын тынычландырырлык сүз эзләп, бераз тын торды. Иплә кенә, кечкенә балаларга аңлаткандай сөйли башлады:

— Беләсең бит, социализм ныгыган саен, сыйнфый көрәш отыры көчәя генә бара. Иптәш Сталин шулай дип өйрәтә...

— Син шуңа ышанасыңмы? Социализм тулысынча җиңде бит инде, әйеме?

— Әлбәттә, җиңде...— Рабиганың саксыз сүзләр ычкындыруын өнәмичә, аны кочагыннан ычкындырды.— Ятыйк булмаса, таң ата озакламый.

— Мине тыңлыйсың килми инде синең...— диде Рабига, үпкәләгән сыман.— Акыллы булгач, әйт алайса, ил тулы «халык дошманы» шартларында ничек җиңеп чыга алган соң социализм?

— Үзең үк әйттең ич, «җиңеп чыгу» дидең. Фәкать көрәштә, аяусыз көрәштә яуланган җиңү бу. Син шуны хәтереңә сеңдер һәм... миңгерәүләр сүзен сөйләп йөрмә! Андый сүзләр ишетелгәли ул, дөрес бәя бирергә кирәк.

— Башка кешегә үз уйларымны чишә торган хатын түгеллегемне беләсең! — Рабига юрган астына кереп чумды. Соңгы сүзләрен чак кына ишетеп калды Әхмәтсафа.— Әхмәровларга да ышанып бетмә, диюем. Менә сез кемнәр хакындадыр тозлап-борычлап чыгыш ясамакчы буласыз. Кайдадыр кемдер синең турында шундый чыгыш хәзерләп утырса?

— Минем турыда? Ни өчен? — диде гаҗәпләнеп Әхмәтсафа.

— Белмим шул...— Рабига, ыңгырашып, стена ягына борылып ятты. –Куркам мин. Синең өчен, балалар өчен куркам...

Иртүк торгач, Әхмәтсафа чыгышны тагын бер мәртәбә карап, төзәтеп чыкты. Рабига белән булган төнге сөйләшү һич тә хәтереннән китми җәфалады.

Беренче мәртәбә тезисларын карагач, Мөхәммәтҗановның җен ачулары чыгып, Абдулла Әхмәров белән Әхмәтсафаны сүгеп ыргытты.

— Яхшы...— диде ул, ачулы тавыш белән. Аннан кабынып ук китте.— Монда язылганнарны трибунага чыгып сайрадың ди инде син, иптәш Дәүләтъяров. Шуннан соң нәрсә буласын беләсезме? — диде, кызарып-бүртенеп торган эшем ияләренә үтләрне сытарлык итеп карап. Шулай да бөтенләй чишелеп, теленә ни килсә, шуны әйтеп ташлаудан да

тыела төште, әмма тәнен яндырып үткән ярсуын бөтенләй үк басып бетерә алмады. — Ни тозы, ни күзе юк бу чыгышның! Кемнәр язган моны? Укып чыкканчы өч мәртәбә исәңгерәп, хәл алдым. Шундый төче, ясалма чыгыш. Хет икегезнең берегез шундый югары трибунадан торып ни сөйләргә тиеш икәнлегегезне чамалый алмадыгызмы? Менә сиңа ике коммунист, ике журналист. Сезнең ише тәти егетләрнең «безнең илдә ал да гөл, фәлән дә төгән» дип сөйләнеп йөрүләренә ышанып торсаң, шымытыр башы тоттырып китәрләр дошман элементлар. Ә бит тирә-якта, кая карама, контрэлемент, милләтче, алар тегерменәнә су коючы сөрсеп беткән надан мыжлап тора. Барысы да караңгы бүлмәдә кара мачы кумакта. Ә сез? Йә, иптәш Дәүләтъяров, шушы бишек җырын көйләгәннән соң сиңа нинди караш булачак? — Мөхәммәтҗанов бөтен гәүдәсе белән каршысында утырган Әхмәтсафа белән Әхмәровка сузылды һәм, тавышын басып, – әх-ти, егетләр, моменттан файдалана белмисез, тимер торыклы корыч коммунистлар түгел сез, салам сыйраклы агач коммунистлар! — дип, нигәдер күз кысып алды. Бу сүзләрнең төбендә зур сер ятканын аңлатырга теләгәндәй өстәп куйды: — Җитәкчелеккә яшь көчләр кирәк, кулга-кул тотынышып эшләрлек ышанычлы иптәшләр кирәк. Бармы алар? Күп түгел, әмма бар. Сезнең белән мин шул күзлектән чыгып эш итәм. Иң югары постларда эшли алырлык яшь көчләр тәрбияләү җиңел түгел. Шулай да ара-тирә күзгә чалынганнарын мин җентекләп күзәтеп барам. Әлегә мин сезгә таянам. Ничек күрсәтерсез үзегезне иң кирәкле чакта, монысы вакыт эше. Аң булыгыз, гражданнар сугышы вакытында, аннан соңгы чорда түргә үрмәләгән надан, сатлык, тормыш диңгезе төбеннән мыштым гына өстәге хәлләрне күзәтеп ятучы сыңар күзле камбала мисле чиновниклар чоры үтеп бара! Мәскәү Татреспубликага туктаусыз кадр әзерләп ятмаячак, берзаман ул ачыктан-ачык ярып салачак: «Җитте, туганкайлар, кадрларыгызны үстерер өчен никадәр мөмкинлек бирдек, үз өегездә үзегез эш оештырырга өйрәнегез, кая кадрларыгыз, кая яңа буын җитәкчеләр, моңарчы нишләп яттыгыз?» — диячәк ул. Шулай бит? Диячәк! Шул чагында аркаларыннан этеп, без кемне алга чыгарырга тиеш булабыз? — Мөхәммәтҗанов, йөзендәге серлелекне зәррә кадәр дә җуймый, көлеп җибәрде. — Бүгенгә җитеп торыр... Башыгыз булса, калганын үзегез дә төшенерсез. Ә хәзер, әйдәгез, Дәүләтъяровның чыгышы хакында сөйләшик. Көрәш бара, рәхимсез көрәш бара, — диде Галим Мөхәммәтҗанов, ике кулы белән өстәленә нык итеп таянып. — Кем кемне? Сорау шундый итеп кискен куелган ки, башка әллә нинди уйлар килеп, тәннәр чымырдап китә. Сез фамилияләрне атамаска тырышасыз, томанлы

фразалар белән сөйләргә азапланасыз, имеш, исемнәр атап, төзәтә алмаслык ялгыш китмәсен. Әйе, бу позиция сезнең өчен дөрес, ләкин мин әйткәнне колакка ныклап киртегез — тегермән әйләнә, ул беркемне дә аямый. Мин күрсәткән фамилияләрне трибунадан кычкырып әйтәсез икән, димәк, инде ул кешеләрне тарих чүплегеннән генә эзләргә кирәк дигән сүз. Йә инде алар кулга алынган, йә көннәре санаулы калган. Сезне аңлыйм, егетләр, кеше язмышы белән шаяру ярамый, тик безгә килеп терәлгәч, безне аяп тотучы булыр микән?.. — Галим, күзен кыса төшеп, бүлмә почмагына карап торды һәм арган тавыш белән дәвам итте. — Чыгыштагы бер генә сүз дә ике уйларга урын калдырырга тиеш түгел. Хәер, сезгә дә аңлау килер, тик соң булуыннан куркам…

Әхмәтсафа үзе дә бу хакта күп уйлана. Әмма сөйләшер, уйлашыр кешесе генә юк. Кемгә, ышанып авыз ачып, сыңар сүз әйтергә белмәссең. Кешеләр торган саен үз эчләренә йомыла баралар. Кичә генә җир җимертеп эшләп йөргән кеше хакында иртәгәсен газета әллә нинди гөнаһларда гаепләп мәкалә кисәге килеп чыга. Күпчелегенең авторы да, язганнарының мантыйгы да юк. Тисә — тияккә, тимәсә — ботакка кебегрәк. Ләкин шул мәкалә басылган газетаны кешедән кешегә күрсәтеп чабулап йөрүче бер хөрәсән табыла. Сүз тарала башлый: утсыз төтен чыкмый ул, диләр… Күр син аны, эт койрыгыннан төз булып йөридерие, панимаешь, эче тулы б… булган икән. Иртәгәсен ул бичара хакында сөйләүче дә, үзен кабат күрүче дә табылмый инде. «Халык дошманы» булган икән теге кабахәт, япун шпиуны. Ярый әле арада бер уяу кеше табылып, тиз арада фаш итеп өлгергәннәр. Юкса күрәселәребез булган икән. Һи, мәлгунь! Менә хәзер сиңа күрсәтәчәк сәвитнең гадел хөкеме! Теге газетада мәкалә бастырган фидакарь затны эзләп табып, орден бирергә иде дә бит, безнең татар халкы тыйнак шул. Дошманны фаш итте, үзенең кем икәнен дә белми калдылар. Менә бу чын гражданин, чын сәвит кешесе, ичмасам. Бу инде хәйлә-акча белән теләсә кемне сатып алырга, теләсә кемгә яла ягып, иманыннан яздырырга мөмкинлекне раслап маташкан, киләчәктә туачак үз эшләренә калын-калын инструкцияләр язып калдырган Аксак Каратун ярчыгы түгел, ә чын намуслылык үрнәге, яңа чор кешесе! Дәшми-тынмый, үз эшен эшли бирә. Газеталарда гына түгел, төрле дәрәҗәдәге җыелышларда да менә шундый «патриот»ларны үсендерү, берберенә яла ягу кебек түбәнлекне яңа чор әхлагының матур үрнәге дәрәҗәсенә күтәрү отыры көчәя бара. Мондый «җилкендерү» эзсез калмый, әлбәттә, бер-берсен сату, арадан «дошман элементлар»ын эзләү, фаш итү көннән-көн киңрәк колач җәя.

Икәү генә калгач, Абдулла Әхмәров аңламаган рәвештә башын боргалап сорау бирде:

— Нәрсә бу, Әхмәтсафа? Нинди җен котыртты сине?.. Безнең төне буе чәкәләшеп-тарткалашып язган чыгышның сөяк-санаклары гына калган димме соң? Ай-һай, подводить иттең, малай. Бу кадәресен көтмәгән идем.

Әхмәтсафа дәшмәде.

## III

Дәүләтъяров илдәге хәлләрне тойса да, бу эшләрнең төбендә ниләр ятканын аңлап бетерми иде. Илгә, халыкка, халыкның рухи дөньясына шушы өер китергән афәтне кем дә булса, кайчан да булса тулысы белән ачып сала алырмы?

Кая карама — фаш итү, кая карама — дошман, дошман... Якты көнгә ышаныч бетә бара. Күршедә яшәүче бер яхшы танышың әле кичә генә шактый югары пост биләп утыра иде, «Кереп чык, чәйләп алырбыз»,— дип, иркен эш бүлмәсенә кунакка да чакырган иде, баксаң, аның «халык дошманы» булуын ачыклаганнар, төнлә килеп алып киткәннәр, ябып та куярга өлгергәннәр икән инде. Бусы чеп-чи немец шпиуны икән. Урам себерүче Кылый Бикә хәбәр итеп өлгергән. Соңга калса, ниләр булып бетәрие микән бу ил? Бичара илнең тышы тулы дошман, эче тулы дошман. Бөтен ышаныч — әнә шул элек атаклы фахишә булып йөргән, бүген элекке «хезмәтен» файдаланып, алдынгы пролетарка саналган Кылый Бикә ишеләрдә — алар йоклап ятмый, бәхеткә каршы, җиң сызганып, НКВДга, ягъни совет властена хезмәт итәләр... Бикә кебекләр исем яшереп тормыйлар. «Билдән түбән үземә дә ышанмыйм, берәрсенә шигем генә төшсен, төн уртасында да чыгып чабам энкеведегә. Ичмасам, анда кайнар чәй эчереп җибәрәләр, өйгә машина белән китереп куялар. Бармас җирдән барырсың кабат»,— дип мактана икән Бикә үзе кебек урам себерүчеләргә. Моны Рабига ишетеп кайтып, кухняда кайнашканда шыпырт кына, әмма бик борчылып сөйләп алган иде...

Әхмәтсафаның да төсе үзгәрде. Кылый Бикә аларның ишегалдын да себерә бит, сак булырга кирәк...

* * *

Докладны әзерләп бетереп, икенче очрашканда Галим инде бераз тынычлана төшкән иде. Әхмәров белән Дәүләтъяров икесе дә ябыгып киткәннәрме соң, йөзләре суырылган, болай да аз сүзле кешеләр, бөтенләй тыңлап торуга гына күчтеләр. Теге чакта Мөхәммәтҗанов әйткәннәр хакында ныклап уй-

ланганнар, эшнең никадәрле җитди икәнен аңлаганнар сыман иде. Күптән түгел генә өлкә комитетының икенче секретаре булып сайланган Галим Мөхәммәтҗановның авыз ачып каласы килми, НКВД кармагына эләкмәү чарасын алдан ук күреп өлгерергә тырыша иде.

Кем кемне? Бу сорау Әхмәтсафага башта сәер тоелган иде, әмма вакыйгалар эченә тирәнрәк кергән саен, аның асылына төшенә барып, май аенда булып үткән партиянең Бауман райкомы конференциясендә ныклап ук аңлады.

Майның унөчендә өлкә комитетының Беренче секретаре Альфред Лепа, Халык комиссарлары Советы рәисе Кыям Абрамов катнашкан әлеге партконференциядә Татарстан дәүләт нәшриятының баш редакторы һәм бер үк вакытта анда партком секретаре да булып эшләгән Әхмәтсафа Дәүләтъяровны Мөхәммәтҗанов «тырышлыгы» белән президиумга тәкъдим иткәннәр иде, Казанга килеп эшли башлагач беренче мәртәбә дисәң дә була, аның исеме шундый зур җыелышта яңгырады.

Әхмәтсафа, санау комиссиясе хисабын тыңлаганда, үзен җайсыз хәлдә хис итте — бер сүз белән генә әйткәндә, фиркадәшләре аны «тәгәрәткәннәр» иде. Бу нәрсә дигән сүз? Районнар дәрәҗәсендә Мөхәммәтҗановның абруен какшатырга, аның белән санлашмаска азапланумы, әллә Дәүләтъяровны «обой»мага алырга иртә әле дигәнне аңлатамы? Әллә Лепа, Абрамовның фатихасы белән Мөхәммәтҗановка каршы хәзер үк уен-муен оештыра башлаумы? «Тәгәрәүгә» Әхмәтсафа артык әһәмият бирмәгән дә булыр иде, әмма тәнәфестә аны Мөхәммәтҗанов үзе эзләп тапты һәм бер читкә алып китеп, кайнарланып сөйли башлады:

— Күрдеңме, иптәш Дәүләтъяров, ниләр майтарып яталар? Коточкыч хәлләр монда тирәннән уйласаң...

Әхмәтсафа аны тынычландырырга омтылды.

— Мине әлегә күпләр белеп тә бетерми. Казанга кайчан гына кайттым бит. Сәбәбен шуннан гына күрәм...

— Сине белмиләрме? Җүләр булма, залда утыручыларның туксан проценты синең белән ТКУда укыган, яки эш буенча яхшы танышларың. Сәбәп башкада — мин тәкъдим иткән бердәнбер кандидатураны «тәгәрәтү» сәяси мәсьәлә ул, брат. — Галим, кайнарланып, йодрыгына йөткереп алды. — Миңа каршы килү бу, «кара шар» салып карадылар разживинчылар. Моның ахыры хәерле бетмәячәк. — Мөхәммәтҗанов әңгәмәдәшен читкәрәк сөйрәде. Аңына сеңсен дигәндәй, өзеп-өзеп сөйли башлады. — Чыгыш ясаганда нык бул, җебеп торма! Күрәсеңме, район ни хәлдә? Сәяси башбаштаклык хөкем сөрә райком аппаратында. Барысын туздырып ташларга! Бу сиңа партия директивасы. Разживинны он-

талкан итәргә кирәк. Күр әле, керфек тә какмый, өлкә комитеты секретаре тәкъдимен аяк астына салып таптадылар диген, ә?.. Татгосиздатның фактик җитәкчесе, партком секретарен президиумга үткәрмәсеннәр инде! Лепа белән Абрамовны күзәтеп тордым, синең исем сызылганда балкып утырдылар, сиздеңме? Разживин алар булганга масая, имеш, таяныр кешеләре бар. Булмый торсын әле. Кем кемне, вот в чем вопрос?! Ил алдында, партия алдында торган сорау менә ничек бөтен кискенлеге белән килеп басты алга... Ә син һаман малай-шалай кебек тотасың үзеңне. Алай булмый ул, брат, безнең эштә вак-түәк юк!

— Кандидатлар регламентта каралганнан артык иде бит, кемдер төшеп тә калырга тиештер инде. Һәрхәлдә, мин моңа ул кадәр үк әһәмият бирү кирәк түгелдер дип уйлыйм. Конференция эшлекле булырга охшаган.

— Кабатлап әйтәм, җүләр булма! Бүгенге көндә марксизм-ленинизм әдәбиятын тәрҗемә итүне үз кулында тоткан коммунистны, өлкә комитеты раслаган китап, брошюраларны дөньяга чыгару белән шөгыльләнгән зур оешманың партия комитеты секретарен санга сукмау — политик хата, хәтта җинаять ул! Йөз туксан тугыз кешенең илле тугызы сине яклаган, үзең уйлап кара, акыл иясе, өлкә комитеты позициясен райондагы партия әгъзаларының өчтән бере генә яклый дигән сүз бит бу. Калганнары ни уйлый, аларга нинди установка бирелгән? Лепа белән Абрамов үткән көн, аларга ышыкланырга тырышу ахмаклык, безгә бүгенге хакында уйларга кирәк. Әйдәле, чыгышыңны тагын бер мәртәбә карап чыгыйк, Разживинны үз урынына утыртмасак, бәябез сукыр бер тиен тормаячак. Безнең әле вакыт бар, синең чыгышны иртәгәге утырышка күчерттем.— Ул Әхмәтсафа кулыннан инде ким дигәндә ун мәртәбә төзәтелеп, ун мәртәбә кабат акка күчереп язылган чыгышны алып, ашыга-ашыга китеп барды.

Икенче көнне вакыйгалар нәкъ Галим Мөхәммәтҗанов уйлаганча булып чыкты.

Әхмәтсафаның усал чыгышын Разживин көтмәгән иде булса кирәк, ул сөйләгәндә үзен шулкадәр уңайсыз хис итте ки, хәтта моны яшерер көче калмыйча, җиңелчә калтыранып, яшелле-зәңгәрле булып утырды.

Дәүләтъяров чыгышында сүз райкомның дәүләт нәшрияты белән җүнле-башлы җитәкчелек итмәве, шуның аркасында киткән идеологик хаталар турында барды. Әхмәтсафа санап үткән фактлар инде берничә мәртәбә партия җыелышларында тикшерелеп, үзенчә чаралар күрелсә дә, Мөхәммәтҗанов аларны трибуна артыннан кабатларга кирәк дип тапты. Хәлнең мондый борылыш алуы Разживин өчен генә түгел, хәтта Лепа, Абрамов кебек коммунистлар өчен дә

үтә куркыныч иде. Чөнки шушы ук гаепләүләрне ике дә уйламыйча өлкә пленумына да өстерәп кертергә мөмкин иде Мөхәммәтҗанов. Лепа белән Абрамов — карт бүреләр, Дәүләтъяров дигән яшь егетнең үз белдеге белән чыгып, трибуна артында шулай очынмавын яхшы аңлыйлар иде...

Бер Мөхәммәтҗанов тыныч тотты үзен, чөнки ул бу постка күптән түгел сайлап куелган иде һәм Дәүләтъяров сөйләгән җитешсезлекләр аның өчен бөтенләй яңалык сыман, гел алга ята төшеп, үтә бер кызыксынган кыяфәт белән тыңлап утырды, ара-тирә алдында яткан кәгазьгә нидер язып маташты. Лепа берничә мәртәбә янында утырган Галимнең касыгына нык кына төртеп аласы килсә дә, бар ярсуын басып, тыелып калды. «Их, җүләр малай, тинтәк баш. Шундый катлаулы вакытта Ленин-Сталин әсәрләре тәрҗемәсендәге сәяси хаталар хакында сүз йөртәләрмени? Башкайларны себер җибәрәсең, агач чырай».

Әхмәтсафаның мондый уенда беренче һәм соңгы катнашуы, әмма бу чыгыш аның язмышын тамырдан үзгәртәсен ул әлегә күз алдына да китерми иде. Ул кәгазьгә язылганны сиптерә бирде:

— Татгосиздат барлык әдәби һәм марксизм-ленинизм әдәбиятын дөньяга чыгару белән шөгыльләнә,— дип сүзен дәвам итте Дәүләтъяров, трибунаның ике канатына нык таянган хәлдә.— Әмма районның партия оешмасы секретарьлары Разживин һәм Долотказин моңа бөтенләй әһәмият бирмиләр. Культура фронтының бу направлениесендә алар инде бүген үк тулысынча тар-мар ителгән дип саналырга хаклы. Әле 1932 елда ук НКВД органнары иң беренчеләрдән булып Татгосиздатта Шәфигуллин һәм аның тарафдарлары булган контрреволюцион төркемне фаш итеп, кулга алулар һәм чистарту үткәрде. Ул чакта ук нәшрият сагидуллинчыларның оясы иде.

«Шәп,— дип куанды Мөхәммәтҗанов,— беренче җөмләләре белән үк кадаклап куйды тегеләрне. Лепага кадәр җыерыла төште әнә. Абрамов, Байчурин ише «карт гвардия» моннан соң яшь көчләр белән санлашмыйча карасыннар инде! Дәүләтъяров тыйнаклык кына күрсәтә, асылда, аны Казанда яхшы беләләр. ТКУ каршындагы аспирантураны тәмамламас борын аны марксизм-ленинизм әдәбиятын тәрҗемә итү эшенә җигүләре үк әлеге фикернең нигезле булуын күрсәтә.

Мөхәммәтҗанов игътибарын чыгыш ясаучыдан алмады. Дәүләтъяров накалны киметми иде.

— Разживин кайчан күрсәң дә үзен эшем иясе кебек тота. Киңәшкә килсәң, ярым-йорты гына тыңлый. Ишетәсе килмәгән сүзгә күчсәң, әңгәмәне икенчегә бора, утырган урынында

кыбырсый, чәбәләнә, кирәкмәгәнгә җикеренә башлый, шулай итеп гади генә мәсьәлә дә чишелә алмаслык төенгә әйләнә. Кузгатылган мәсьәләнең төбенә төшү турында уйлап та карамый. Колагына алдан кем нинди ялган пышылдап өлгерә, аның өчен иң дөресе шул. Контрреволюцион троцкийчы Рәхмәтуллин, Гыймранов, Шәфигуллин, Гомәровларга яңа партия билетлары биреп чыгарганда кем сүзенә колак салган микән? Ә «халык дошманы» Шәфигуллин узган елның август урталарына кадәр Татгосиздатта партия оешмасы секретаре булып торган. Разживин кайда йөргән? Болар бит пүчтәк сораулар түгел, боларга җавап бирми хәле юк Разживинның.

Альфред Лепа янә бер мәртәбә ачу белән Мөхәммәтҗановка караш ташлады. Галим, уйларына йотылып, борын очын сыпыргалап утыра иде.

— Без соңгы чорда нәшрият чыгарган китап продукциясен тикшереп, утыз дүрт исемдә дәреслекне чүпкә озаттык, — дип дәвам итте Дәүләтъяров.— Гомуми суммасы — җиде йөз мең сум. Мәсәлән, Сәлах Әтнәгулов редакторлыгында чыккан Бадыйков язган дәреслекне алыйк. Унҗиденче битне ачып укып карыйк: «Карл Маркс, Сталин, стандарт, крахмал, крах, марксизм, старик, Энгельс, элемент һәм башка шундый янәшә торырга һич тиеш булмаган төшенчәләр, аңлатмалар, төрләндерүләр белән шыплап тулган бу бит. Балаларның аңын бутау өчен моннан да кулай юл юктыр. Икенче бер дәреслектә «җете кызыл тиз уңа», «авызын ачса, үпкәсе күренә» дигән, әллә кайчан тарих чүплегенә очарга тиешле мәкальләр урын алган... Без мондый юл белән бара алмыйбыз!

Дәүләтъяровның чыгышы хупланды. Гөрләтеп кул чабулар астында ул үз урынына ничек килеп утырганын да сизмәде. Каушау галәмәте булдымы, ул инде башка чыгышларны ишетмәде. Хуплавын хупладылар чыгышын, әмма трибунадан төшеп, бераз утыргач, күңелен авыр уйлар биләп алды. Ярамаган эш кылган төсле хис итте үзен. Күз алдында исә Мифтах хәлфәнең томанлы шәүләсе йөзә, таягын күтәреп Әхмәтсафага табан селки-селки кылә кебек, үзе көйгә салып бер үк сүзләрне кабатлый: «Алай түгел бит инде, болай түгел бит инде, үзегез чокыр казыйсыз, үзегез төшеп бетәсез бит инде!» — Әхмәтсафа Мифтах хәлфәнең: «дөрес, әмма алай түгел ул» дигән сүзләрен шулкадәр ишетергә тели, түземсезләнеп көтә. Ләкин хәлфә һаман үзенекен кабатлый: «Алай түгел бит инде, болай түгел бит инде, үзегез казыган чокыр... Их!..» — диде дә Мифтах хәлфә каядыр юкка чыкты.

Залда җанлылык хөкем сөрә — тәнәфес игълан иткәннәр икән.

Аны бу сәер халәттән Мөхәммәтҗанов сүзләре генә айнытып җибәрде:

— Шәп, егет, тегеләрнең саруы кайнарлык булды!

— Шулаен шулай да... — диде, аптыраулы тавыш белән Әхмәтсафа. — Чокыр бит тирән казыла, барыбызга да җитәрлек...

Мөхәммәтҗановның күзе маңгаена тәгәрәде.

— Син нәрсә сукалыйсың, брат? Хәзер үк тынычлан, акылыңа кил! Иң әйбәте — өеңә кайтып ял ит. Нервың бирешкән, парин. Без бит юлның башында гына әле, болай тиз бирешү һич тә ярамый. Көрәшкә чыккансың икән — билеңне бирмә инде. Аң бул — без дөньяга җиңелү өчен килмәдек!

* * *

Конференциядән соң Әхмәтсафа шактый вакыт үзенә урын таба алмый йөрде. Әле аңа кадәр үк, төшке ашка кайтканда, ишегалдындагы бала-чаганың уйнаганнарына күз салган иде, имәнеп китте: сары чәче матур итеп тасмалап үрелгән кызчык дәү генә гәүдәле, таушалган кыяфәтле курчагының сыңар аягыннан эләктергән дә, дөньяның бер ай-һаена исе китмәгәндәй, эсседән куырылган сукмак буйлап каядыр бара. Ара-тирә курчагына зәһәр сүзләр ычкындырган була, ачуы килгән, ахры, уенчыгына. Әхмәтсафаның исен җибәргәне — кызчыкның уенчыгына болай миһербансыз кылануы гына да түгел иде, ә курчакның шундый төче елмаю белән тузанлы сукмактан өстерәлеп баруы иде. Аның бу халәтенә дә, кызчыкның энәле сүзләренә дә исе китми, алар әллә бар, әллә юк, һаман бер көйгә елмаеп тик бара. Шуның өчен дә курчак шул ул, җансыз курчак.

Курчак язмышы... Үз язмышын оештырудан мәхрүмлек... Сискәнеп китте — чынлыкта ул үзе дә кайбер кешеләр кулында курчак кына бит. Чарасызлык, һәр порученииене өлкә комитеты исеменнән бирелгән установка дип кабул итү күпмегә кадәр дәвам итәр? Кире чигенеп тә булмый.

Галим дөрес әйтә, уенга кергәнсең икән, җебеп утырма!

Конференциядән соң моны ул ачык сизде, бер генә кеше дә, Мөхәммәтҗановтан башка, әлбәттә, аны «шәп» чыгышы белән килеп котламадылар. Баштагы көннәрдә танышларның күбесе читләтеп тә үтәләр иде әле. Дәвере өчен табигый хәл — алар моның ахыры ни белән бетәсен көттеләр бугай. Ә бит аны икенче көнне үк НКВД «җыештырып» алып китәргә мөмкин иде... Уенга кергәнсең икән, кире чыгу турында уйлама, югыйсә ниндидер куәтле машина сине «эһ» итәргә өлгергәнче сытып кына узачак. Күз алдына Рабига, үсеп килүче уллары Марат белән Марлес килә дә йөрәге кысылып куя. Курчак үзенең язмышы өчен көрәшүдән мәхрүм. Уенчык язмышы шуннан гыйбарәт. Ә ул, адәм баласы

җәмгыятьтән аеры башка чыгып, илдә барган барлык вакыйгаларга кул селтәп, үзе өчен генә яши аламы, шушы катлаулы чорда үз язмышын оештыру хокукы бирелгәнме аңа?

Бер мәртәбә конференциядә чыгыш ясап, күзгә төртеп торган кимчелекләрне иптәшләрнең йөзләренә бәреп әйткәч тә, шыксыз үрдәк баласы булып йөр инде. Нәрсә бу? Акылга хилафлыкмы, тыйнаклыкмы, мокытлыкмы? Агымдагы сәяси хәлләрдән бихәбәр түгел ич — ил буенча шундый конференция-җыелышлар үтүен, аларның һәркайсында үзтәнкыйть, үзара тәнкыйть дигән нәрсә үзәктә булып, моңа инде җитәкчедән алып гади партия әгъзасына кадәр чыныгып, пешеп баралар иде. Тәнкыйть белән чыгучыларга үпкәләп, гаепкә санап йөрүчеләр бик аз була. Гадәттә, җыелышның ниндирәк тәнкыйди рухта үтәчәге беренче минутларда ук беленә, тонны үзтәнкыйть штыгы белән коралланган район яки өлкә җитәкчесе үзе үк бирә.

Җыелышлар исә дәвам итә. Татгосиздатта көн саен диярлек үткән партия җыелышлары да кайнарлыктан мәхрүм түгел, язучылар сүзләрне сайлап тормыйлар, Әхмәтсафага нигәдер Фатих Кәрим өчен нык эләкте.

Беркөнне язучылар йорты каршында Фатих Кәримнең моңсуланып, аптырап басып торуын күргәч, аның янына бармый кала алмады Әхмәтсафа. Керпе чәчле, һәркемгә хәер хаһлы бу егетне үз итә иде ул. Әмма әле күптән түгел булып узган бер җыелышта аның бөтен иҗатын да, үзен дә туздырып ташладылар: контр, имеш, мулла малае булуын яшереп йөри, үзен массалар алдында фаш итми. Язганнары тулысы белән советка каршы икән. Менә шул чактан бирле аңа көн юк инде. Хәл-әхвәлләрне сорашкач, Фатих ачынып:

— Француз инкыйлапчысы дөрес әйткән, иптәш Дәүләтъяров, килә шундый вакыт, революция үзенең балаларын ашый башлый икән. Менә бит нинди хәлдә калдым, гаилә ишәя, торырга урын юк, балаларга ашарга тәгам ризык табып булмый, кесәдә сукыр бер тиен калмады. Кая барырга, кемгә баш иярга? Нинди гөнаһлар өчен диген?..

Әхмәтсафа «аңлыйм хәлләреңне» дигәндәй дәшми генә тыңлап торды да Кәримне, иске кәчтүн җиңеннән сак кына эләктереп, үзе белән әйдәкләде. Бухгалтериядә аласы гонорары булган икән, «дошман» дип табылгач, бирми тотканнар, бар җаваплылыкны үз өстенә йөкләп, шул акчасын бирдертте.

Бу хәл көне-сәгате белән Язучылар оешмасына барып та җиткән иде.

Июнь аенда Әхмәтсафа Дәүләтъяровны «Кызыл Татарстан» газетасының җаваплы редакторы итеп раслады лар. Нәш-

риятның партия оешмасын типографиядән аерып, аның тәүге сәркатибе итеп Нур Баян сайланды.

...Бу хакта кайта-кайта уйланды Әхмәтсафа. Ни өчен нәкъ менә аңа тукталдылар өлкә комитетында? Журналистикада ат уйнаткан кешеләр аз түгел иде бит. Белем ягыннан да, тәҗрибә ягыннан да, һөнәр иясе буларак та Фатыйх Сәгыйтов аннан кимме?

Эш бүлмәсенә чакырып, аны җаваплы редакторга «кодалаганда» бу хакта Әхмәровка ачыктан-ачык әйткән иде. Аңа кадәр эшләгән Ризванов, Рәмзи, Еникеевларның язмышы да күңелне тырнап тора. Барысын да «дошман» ясап бетергәч ни. Ул нәшриятта эшләсә дә, күбрәк хуҗалык йөген тартты. Монда исә иҗат белән бәйләнгән вазифа. Үзең җүнләп белмәгәнне башкаларга ничек өйрәтәсең дә, башкалардан ни рәвешле эш таләп итәсең?..

Әхмәров аны сабыр гына тыңлап торды. Чигенергә урын юк икәнен сиздерергә теләп, сүз башлады.

— Мөхәммәтҗанов белән бүген генә танышкан кеше түгел син, әйеме? Холкын яхшы беләсең. Синең кандидатураны чыгарган икән, димәк, уйланмыйча гына кылынган гамәл түгел бу. Бу хакта, хәтерем алдамаса, сиңа Галим Мөхәммәтҗанович элегрәк әйтеп-сиздереп куйган иде булса кирәк... Үзем дә «Кызыл Татарстан»ны беренче очраган кеше кулына тапшырырга теләмәс идем. Ут-сулар кичәрлек иптәш син. Сирәк хәзер андыйлар.

— Рәхмәт... Зурлыйсыз зурлавын да, ышанычны аклап булыр микән? Теге чакта Мөхәммәтҗанов «җаваплы редактор» дип сүз кузгаткан иде, әмма мин ул вакытта аны чынга алмадым, шаярту дип уйладым. Баксаң...

Абдулла Әхмәров, башын артка ташлап, көлеп җибәрде.

— Баксаң, без шаяртырга исәп тотмыйбыз.— Көлүеннән кисәк туктап, җитди рәвештә өстәп куйды.— Эшне белмим дигәнеңә ышанып бетмим, син инде бу өлкәдә күп уралдың. Кемнең ни эш майтарырга сәләтле булуын гына беләбез. Сәгыйтов кулына калсаң... ТКУда белем алганнарның бер начар гадәте бар — алар үзләрен башкаларга караганда өстен тоткан булалар. Янәсе, белемлерәк, дөнья агышын яхшырак күзаллыйлар. Аларда тәнкыйди рух көчле. Тик еш кына, сүз булмаганда, сүз булсын, ата казың күкәй саламы дигәндәй, тәнкыйтьләре тисә — тиенгә, тимәсә — ботакка килеп чыга. Сәгыйтовның да эшенә караганда тавышы күбрәк. Синең холыкка капма-каршы кеше. Журналистлар арасында Сәгыйтов ишеләр күбрәк шул. Карышып, Мөхәммәтҗановның ачуын гына китерерсең. Бу синең файдага да түгел, минем абруйга да зыян килер. Алын син бу эшкә...

— Бер мәкалә дә язмаган башым белән…

— Язганнарың җитәрлек, районнарда эшләгәндә язмаларың чыккалап торды ич.

— Пәри башка, җен башка…

— Ярый, сүз бозау имезә, йә синтетик каучук төзелешеннән, йә икенче ТЭЦтан берәр язма әзерлә дә бүген үк редакциягә илтеп бир. Мин хәзер сөйләшеп куям, язганыңны бүгенге номерга кертсеннәр.

— Әйтергә ансат. Ни турында язарга? Бөтенләй читен хәлгә куйдыгыз әле…

— Җебеп торма, Әхмәтсафа, сиңа килешми. Тот та профсоюзларның эшен тәнкыйть итеп яз. Аларны күпме сүксәң дә рөхсәт ителә, башкаларга гына кагылма. Ә инде бүген үк басылып чыгарырлар дигәнгә аптырама, яңа җаваплы редакторның беренче мәкаләсен инде көтеп тә торалардыр.

Әхмәтсафаның хәзер генә исенә төште. Күпме сүз куерттылар, сорарга онытып тора икән.

— Бәй, Еникеевка ни булган?.. Ярыйсы гына эшләп йөри иде бит.

— Син сорама, мин әйтмим,— диде Әхмәров, бу сүзләргә күп мәгънә салырга тырышып.

Әхмәтсафа, Мөхәммәтҗанов белән Әхмәровның теләгенә янә каршы төшәргә базмыйча, үзенә бераз таныш булган ТЭЦ төзелешенә чыгып китте. Анда профсоюзларның еллык хисап җыелышлары үткәрелгәнен кемнәндер ишетеп калган иде…

Кечкенә улын күтәреп, Җамал килеп керде. Баласын урындыкка утыртып куйды да, иреннәрен нык кысып, Әхмәтсафага төбәлде.

— Эштә бер-бер хәл булдымы? — дип сорамый түзә алмады бүлмә хуҗасы.— Малай ничек, бик көйсезләнмиме?

— Үсә…— диде Җамал, боек тавыш белән.— Менә синең хәлне белергә килдек әле, әйеме, бәләкәч коммунарым минем!

— Бәкәчем, дисеңме? — Әхмәтсафа шаяртасы итте.

— Тозсызланып утырма инде, синең эштә болай сөйләшү килешми. – Җамал шыңгырдый башлаган улын кулына алды.— Әллә син аны әтисез үсә дигәч тә? Аның әтисе совет власте, шаярма, абыйсы!..

Җамал бервакыт бик каты мәхәббәт утларында янып алды. Егете хәрби заводта эшли иде, Казанның бер заводында бүлек мөдире вазифасын башкара. Техник әдәбиятка мөкиббән, еш кына Җамал эшләгән китапханәгә килә. Шунда танышып киткәннәр иде. Эш уеннан узып, Җамал үзенең авырга узуын әйткәч кенә егет дигәннең инде өйләнгән, шулай ук бәби үстереп ятулары билгеле була. Җамал күтәрелмәде, бәрелмәде, язмышына төшкән чираттагы сынау гына

дип кабул итте бу хәлне. Исән-сау бәби алып кайтты һәм берни булмагандай теге адәм белән очрашуын дәвам итә иде.

— Ныклап уйлап керештеңме бу вазифага? — Җамал сынаулы карашын Әхмәтсафага төбәде.

— Нәрсә дип әйтим инде. Уйлаган кебек идек тә...

— Уйлагансың, пычагым. Минем белән киңәшкән булыр идең, бөтенләй санлашмый башладың. Рабига белән сөйләшкәнсеңдер инде, ачуым бер килмәгәе, ул ни диде?

— Синеңчә уйлый...

— Ә мин ничек уйлыйм?!

— Каршы...

— Ничек риза булдың, егетем, бу эшкә?.. Күрмисеңме, сиңа кадәр эшләгәннәрне нишләттеләр? Куркам мин, Әхмәтсафа, хәзер һәрнәрсәдән куркам. Күңел түренә кереп оялаган да курку, көне-төне җанны талый. Шуңа килдем, чигенергә мөмкинлек булса, калдыр син бу эшне... — Җамалның тавышы калтырап чыкты.

— Без чигенсәк, менә бу коммунарлар ни уйлар безнең хакта? — Әхмәтсафа әнисе алдында тибенеп утырган сабыйны кулына алды. — Поезд үтте инде, чигенергә ярамый...

— Сак бул инде берүк, мин бит сиңа карап торам. Минем өчен дә бердәнбер терәк син. Үзем генә булсам ярый иде, инде хәзер шушы сабыем да булгач... Марат белән Марлес ничек матур булып үсеп киләләр. Сак бул, зинһар, ызгышгаугалардан ерак тор! — Җамал, Әхмәтсафага күтәрелеп карамыйча гына, улына үрелде. — Без китик инде, эшең күптер. Ачуланма, турысын әйтми түзә алмадым... — Хатын яшьле күзләрен яшереп, улын күкрәгенә кыса төшеп, чыгып китте.

...ТКУда аспирантураны тәмам кылгач, Әхмәтсафага берничә эш урыны тәкъдим иткәннәр иде. Ул үзенә таныш булган Минзәлә төбәген сайлады һәм аны МТС политбүлеге урынбасары итеп билгеләделәр. Монысына кайгырмады Әхмәтсафа. Кешеләр белән эшләүне, тормышның үзәгендә кайнауны ярата иде ул. Казанга якын түгел түгелен, ләкин бит Бохара ягына китеп олагу да түгел. Инде ике улы — Марат белән Марлес үсеп килә. Рабигасы үз янында, тагын ни кирәк?

Анда ике еллап эшләгәч, 1935 елның язында, Кызыл Йолдыз райкомының икенче секретаре итеп Котлы Бөкәшкә, Казан ягына җибәрделәр. Җитмәсә, мәгез дигәндәй, язмыш алар янына Җамалны да китереп кушты — аны ТКУдан соң райком инструкторы итеп өлкә комитеты Кызыл Йолдызга билгеләгән икән. Җамалның килүен барысы да шатланып каршы алдылар. Инде хатынның җилләнеп-дуамалланып йөрүе чигә төшкән, ул басынкыланып, сабырланып калган иде. Каршы төшми тыңлап утырсаң, һәр сүзендә тәҗрибә, һәр сүзендә алтынга тиң акыл иде аның. Әхмәтсафа белән Раби-

га үзләре дә, балалар да Җамалга шулкадәр ияләшеп беттеләр, аның белән киңәшмичә бер эшкә тотынмыйлар, аннан башка хуҗалыкта бер гамәл кылынмый иде. Әгәр Җамал кайтып җитмәсә, ашарга да утырыш юк.

Шуңа күрә Әхмәтсафаны кабат Казанга, тәрҗемә эшенә нәшриятка кайтаргач, иң беренче эше шул булды, җаенсәбәбен табып, Җамалны да янә шәһәргә чакыртты һәм китапханәдән эш урыны табып бирде.

Хатын күңелгә вәсвәсә салды. Үзенең нинди урында утырганын яхшы аңлый да ул, тик менә ызгыш-даулардан ни рәвешле читтә калып була? Бөтенесе бергә буталышып, укмашып беттеләр ич инде, уңнан да, сулдан да урап үтмәле түгел каршылыкларны, күзне шар ачып нәкъ өстенә барырга туры килә.

## IV

Кабинет хуҗасы каршысында ашыга-кабалана хисап тотучы Маленковны гадәттәгедән озаграк тыңлап торырга тели иде, ахры, йомшак терәкле урындыгына ята төшеп, трубкасын күгелҗем итләч иреннәренә кыстырып куйды. Күзләре кысыла язып бетте.

Маленковны, һич тә булмаганча, түземсезләнеп көтте ул. Татарстан Солтангалиевләре, Сәгыйдуллиннары, берсе өстенә берсе килеп төшкән әләк-жалобалары белән аның үзәгенә үткән иде. Моңарчы җибәргән бер генә ӨК сәркатибе дә аның өметен тулысынча акламадылар. Бераз эшләгән булып кыландылар да дошман сафына кушылдылар. Казан күптәннән аның күзен кыздыра, Мәскәүдән кала, иң көчле бухаринчылар да шунда булырга тиеш, аңа калса. Менә шушы шикләрен куып таратырдай гамәл кылырга кирәк иде. Сталинның шәхсән күрсәтмәсе нигезендә, 1937 елның август ахырында Маленковның Казанга сәфәре махсус шуның өчен оештырылды. Ул урынга барып, «дошман» оясына төп удар ясарга, туздырырга, исән калган «дошманнар» өерен кыйратырга, Татреспублика җитәкчелеген тулысынча алыштырып, уңга-сулга тайпылмаслык кадрлар белән ныгытырга, моннан соң Казан ягыннан вәсвәсәле хәбәрләр килмәслек итәргә тиеш иде.

Сизә, чынлап сизә Маленков Сталинның аннан нинди рәк доклад көткәнен. Август ахырында Казанда булып, өлкә комитетында берничә көн дәвам иткән пленумнан тәмам кайнарланып кайткан әнә. Татарстанга җибәрелгән махсус комиссияне җитәкләгән ҮК вәкиле Георгий Маленков юкка гына дәүләт ипиен ашамаганлыгын расларга тырыша, Казанда эшләрнең коточкыч таркау итеп күрсәтүдә сүзләрне җәлләп тормады докладында. Ярый әле иптәш Сталин, даһиларча алга ка-

рап эш итә, ярый әле Казанга башка беркемгә ышаныч күрсәтмичә, аны, Маленковны җибәргән юлбашчы. Ярый әле вакытында удар ясалды дошман өеренә. Соңга калынса, контр оясына әйләнгән Казанданиләр булып бетәсен чамалавы да кыен. Бу сүзләр Сталинның күңеленә хуш килде.

Маленков, чыннан да, Казанда үтә мөһим эш кырып кайтуын гамәли мисалларда оста һәм саллы итеп күрсәтергә омтыла, тырышуы шул чиккә җитте, инде ике битеннән шыбырдап тир ага, ул аны кулъяулыгы белән сөртеп өлгерми, Сталин исә, торган саен йомыла бара, әллә бар Маленков, әллә юк, шулкадәр дәрәҗәгә җиткән контр оясын тузгытып кайтып, рәхмәт сүзен ишетмәсә ишетмәс, хет инде хуплауны белдергән сыңар ишарә эләктерү генә дә ни торыр иде бу мәлдә. Әмма Сталинны серле иткән сыйфатларның берсе шул: ул каршысындагы кешенең җаны табан астына төшеп, сыңар аягының чәнти бармагы арасында бәргәләнә башламыйча, ым да какмаячак. Маленков Казаны-ние белән томанга кереп югалды сыман, юлбашчы исә бөтенләй икенче дөньяда йөзә кебек иде. Шушы уйдан миңгерәгән хәлдә, Маленков кисәк туктап калды.

Бүлмәдә беразга гына урнашкан тынлыкны Сталинның салмак, ачык тавышы җимереп ташлады:

— Шулай да иптәш Маленков, әйт әле, Татобкомда кадрлар мәсьәләсе ниндирәк хәлдә?

Каударланып җавап тота башлады Маленков:

— Лепадан соң...

— Ул карт беләт хакында сөйләп тормасаң да була. Ежов егетләре кулында ул, Троцкийның артын ялап кабарткан корсагын тиз шиңдерделәр НКВДда... Яңалар, булдыклылар, таянырлык иптәшләр бармы?

— Бу хакта, иптәш Сталин, көне-төне уйландым, үземә бирелгән вәкаләтләр кысасында кайбер карарлар да кабул итәргә туры килде. Татреспубликада контрларга каршы беренче, ләкин хәлиткеч удар ясалды дип исәплим, әмма эшне ахыргача җиткерү өчен нык көчәнергә туры киләчәк. Казан көндәлек игътибарда минем хәзер, эшне ярты юлда калдыру дөрес булмас иде. Бер генә кешегә — Алемасовка таянырга була. Эшне тарта алырлык, каты куллы җитәкче. Партия эшенә тугрылыклы булуы һәр сүзендә чагыла. НКВД наркомы булып торган бер ай эчендә шактый эшләр майтарды. Тәҗрибәле иптәшләрнең сүзләренә караганда, яхшы якка үзгәрә хәл.

— Сүзләр дисең инде...

— Гамәлләр дә җитәрлек, иптәш Сталин. Кыска гына арада күпме «халык дошманы»ның койрыгына басты. Яланкулдан гына эләктереп ала торган еланнар түгел алар. Абрамов, Байчурин, Лепа... Кыскасы, әгәр Алемасовка Казан уртасында Мисыр пирамидасы салдырып куярга кушасың икән, анысын да

эшли ала торган кадр. Аның өчен вакыт та, чик тә юк. Башка сыймый, һәркайсы артель оештырып өлгергән башкисәрләрне нинди тизлек белән фаш итеп, сасып яткан караңгы ояларыннан якты дөнья йөзенә чыгарды ул?!

Сталинның йөзе мәзәк төскә керде.

— Мисыр пирамидасы?.. Ә нигә кирәк ул анда?

— Болай гына әйтүем, иптәш Сталин. Уңышсыз мисал китердем, гафу итегез. Чыннан да, Алемасовка ышанычым зур.

Сталин урыныннан калкына төште.

— Аңа ышанычны Үзәк Комитет күрсәтте. Ә пирамидага килгәндә... Кызык фикер бу...

Маленковның эченә җылы йөгерде, аяк бармаклары кызышып алдылар.

* * *

Александр Алемасовны Казанга 1937 елның җәендә НКВД наркомы итеп җибәрделәр. Аңа кадәр нарком булып эшләгән Петр Рудьны Татарстанда мыжлап торган контрреволюцион җитәкчеләрне фаш итүне үзагымга куюда, фаш ителгәннәрнең «телен» ачтыру эшендә йомшаклык күрсәтүдә гаепләп, җәй башында Мәскәүгә чакыртып алдылар һәм тиздән үзен үк контр ясап, атып та үтерделәр.

Рудь тырышмаган түгел иде, тырышкан да кебек иде болай үзе, әмма Мәскәү аның эшеннән канәгать булмады. Рудь акланып маташты. Эш-гамәлләрен санады, тик бер «дошман» исемлегенә теркәлеп куйгач, аның «тырышлыкларына» артык игътибар итүче булмады. Рудьның күзгә күренерлек «эше» бар иде барлыгын.

Утыз алтынчы елның җәй-көз айларында Татарстан дәүләт китап нәшриятында контрреволюцион оешма «фаш» ителеп, Исхак Рәхмәтуллин, Сәлах Әтнәгулов, Фатих Сәйфи-Казанлы, Зәки Гыймранов кебек милли кадрларны «Черек күл»гә озатуын ул аеруча горурлык белән телгә ала иде. Ләкин аның бу эшне тиешенчә башкарып чыкмауда гаепләделәр. Милләтчеләрнең гөнаһлары конкрет ачылмады, ачылганы тиешенчә халыкка хәбәр ителмәде. Аларның эше Алемасов килгәч кенә ахырына җиткерелеп, «милләтче-контрреволюционерлар»ның арт сабакларын укыту, атулар башланды. Алемасовның каты куллы чекист булуына Сталин тамчы да шикләнми иде, инде бу хәлләрдән соң, бигрәк тә Маленковның нотыгыннан соң, аңа ышанычы тагын да арта төште. Александр Алемасов утыз биш яшьлек ир-егет, зур эшләрдә үзен күрсәтерлек, өлгереп җиткән партия работнигы, инде ун ел дәвамында илнең төрле өлкәләрендә җаваплы постлар биләде. Себердә, Украинада партия эшендә үзен күрсәтә алган Алемасов, Сталин уенча, Казан өчен үтә кирәкле

кадр иде. Дүрт ел дәвамында Татарстан партия оешмасында контрреволюцион төркемнәр үрчеп ятуын күрмәгән-сизмәгән ялкау ата песи Альфред Лепаны алыштыру өчен менә дигән кандидат иде ул. Шуңа күрә дәүләт куркынычсызлыгының өченче ранглы комиссары Алемасов кандидатурасы хакында сүз куера төшкәч, Сталинның йөзендә җиңелчә генә яктылык пәйда булды.

— Алемасов ышанычлы дисең инде... Килешәм, әлегә безнең ышанычны аклый ул... Ә калганнары?

— Калганнары... Миңа ӨКның икенче секретаре Мөхәммәтҗановның пленумда Вольфовичның тетмәсен тетүе ошады.

— Вольфович? — Сталин бу фамилияне ишеткәч, чыраен сытып куйды. — Үзәк Комитетның рекомендациясе белән китеп, Казанда бәдрәф сасысы чыгарган ул ишәккә тиешенчә отпор бирә алдыгызмы? Фиргавен! Менә кем анда тере килеш мумиягә әйләнде. Ә син пирамида дисең! — Генсекның тавышында тимер катылыгы чагылып китте.

Бәхетсез башка тимер тарак. Каян килде телгә бу пирамида сүзе,ә? Маленковның күзендә яшь бөртеге елтырады.

— Бирелде, иптәш Сталин, ул ишәк... фиргавен... Вольфович тиешлесен алды дип уйлыйм. Башта мин тыңлап кына утырдым, сизеп торам – йомшак бара тикшерү. Халык шулкадәр инерциягә өйрәнгән. Җирле фирка башлыкларына мәсьәләнең төбен ныклап аңлатырга туры килде, иптәш Сталин. Әгәр дә эш болай барса, моннан чыккан кеше булмаячак, пленумыгызны тулы составта НКВД кулына тапшырам, дип, революцион позициядә нык торуымны күрсәтергә туры килде, иптәш Сталин... Шуннан соң гына халыкның теле чишелде.

Сталин сөйлә дигәндәй ияген кагып куйды. Аңа пленумны тулы составта НКВДга озату идеясе ошады бугай. Йөзе яктыра төште.

— Егерме алтынчы августта үзем бик каты тордым, авыз эчендә ботка пешерүчеләргә бернинди пощады булмады. Әйтәсең икән, фикереңне кистереп әйт, йә төрмәгә юлың, йә партия көрәшчесе син. Шигарь шулай куелды. Кичке утырышта Алемасов егетлек күрсәтте. Өлкә комитеты әгъзаларын урыннарыннан кубарып, һәркайсыннан Вольфовичка карата хөкем сүзләрен әйттерде. Эчке каршылыкны шулай бергәләп сындырдык... Алемасов, иптәш Сталин, аерым әңгәмә вакытында ышанычыгызны аклаячагын кат-кат белдерде. Өлкә комитетның Беренче секретаре итеп сайлануын да дөрес кабул итте.

— Башкалар ни уйлый?..

Әйтергәме-әйтмәскәме дигәндәй, бераз уйланып торганнан соң, тәвәккәлләп, дәвам итте:

— Постка Мөхәммәтҗанов ымсынган булса кирәк. Мин моны Казанга килеп төшеп, иптәшләр белән фикер алышуга ук тоеп алдым. Башта ләм-мим дәшмәдем Үзәк Комитет фикере хакында. Тел тегермәннәре тарта бирсен, ачылсыннар әле, мин әйтәм. Үзенчә эш тә йөртеп маташкан бугай Мөхәммәтҗанов, ләкин мин килгәч, бу хакта авыз ачып фикерен белдермәде. Югыйсә тарафдарлары да булгандыр. Иптәшләрнең тел төбеннән шуны сиздем. Милли кадрларга юл ачарга кирәк, дип әйтүчеләр дә булгалаган. Андыйларны, билгеле, мин килгәнче үк җыеп алып бетергәннәр иде. Ачыктан-ачык эш йөртмәгәч, Мөхәммәтҗановка әлегә кагылмыйча тордык. Кемнәргә исәп тота, ачыкланып бетсен, дидем... Солтангалиевче булып чыкмагае дип тә уйлаучылар бар. Әмма, әйткәнемчә, әлегә андый егет кирәк анда, кагылмаска куштым. Тирәсенә берәр артель туплый икән, ул чагында барысын бер капчыкка тыгып, каталажкага илтеп бушату күпкә нәтиҗәле булачак.— Маленков Сталинга күтәрелеп карады, «халыклар атасы» аның сүзләрен игътибар белән тыңлаган сыман иде. Инде иң мөһим хәбәрне дә әйтер чак җитте. – Алемасовны өлкә комитетының Беренче секретаре итеп сайлау турында Сезнең тәкъдимне керткәч, кикриге шиңде пленумдагы татар малайларының. Алемасов тирәсендә бөтерелеп, чабышып йөри башладылар.

Юлбашчының йөзендә әллә ни үзгәреш сизелмәде. Шулай да Маленковның эш алымы күңеленә хуш килде шикелле, үз фикерен белдерүне дә кирәк санады.

— Бераз гына аларга юл биргән сыман кылансаң да, зыян булмас иде... Милләтчелек бик оста яшеренгән, тирәндә яткан нәмәстә ул. Татарларның кылларын тарткалап, уйнатып алу кирәк ул андый чакта, кирәк...— Сталин, трубкасын авызына кабып, Маленковка сынаулы караш ташлады.— Әйт әле, иптәш Маленков, Вольфович мәсьәләсе шул дәрәҗәдә җитди идеме?

— Җитди, иптәш Сталин. Белгәнегезчә, Вольфович танылган галим санала, Татреспублика партоешмасының тарихын язуда төп фигураларның берсе. Әлеге мөһим эшне аңа тапшыру үзе дошманлык акты саналырга хаклы. Бу чын тарих буларак, иптәш Сталин, Сезнең җитәкчелектә милли республикада социализмның тулысынча җиңүен һәрьяклап күрсәтергә тиешле саллы хезмәт булырга тиеш иде. Эш узагымга куелган, ахырда нәрсә килеп чыга? Тарихны язуга ТКУ ректоры Вольфович «халык дошманнары»н тарткан һәм шулар позициясеннән чыгып язылган китап пәйда булган Татарстанда. Социализм төзелешенең Сез күрсәткән принципиаль платформасы бик тонык шәйләнә.

— Карт алаша. Тәки акылга килмәде, кабахәт...

— Шуңа күрә Лепа кебек контрреволюционерлар куены-

на елышкан да ул. Һәм бу өтек кысланы чиста суга чыгару эшенә турыдан-туры үзем җитәкчелек иттем дә. Тарихчы Вольфович җитәкләгән элекке Татар коммунистик университет лабораториясенә кереп оялаган «халык дошманнары»н, андагы җылы өннәреннән комсыз кумакларны өшкереп чыгаруга ирешү — Татреспубликада хәлләрнең рәтләнә башлавы дигән сүз, дигән карарга килде комиссия һәм төп удар шуңа күрә Вольфовичка ясалды да. Ул үзенең партия стажына сылтау ясап, белеменә, тәҗрибәсенә таянып, күпләрнең башын болгатып яткан Казанда. Дөресен әйткәндә, данлыклы Казан фән мәктәбен Вольфович үз тозагына эләктергән... Инде ул фән мәктәбе дип сөйләнүләр көлке дисәң дә ярый.

Бу мәсьәләдә Сталин үзенең төшеп калганнардан түгеллеген күрсәтәсе килдеме, авырыксынган кыяфәттә:

— Лобачевский чорыннан ук болгана Казанда фән мәктәбе,— диде ул, күзенә төтен кермәсен дигәндәй, керфекләрен түбән төшереп.— Казанда потенциал бар дип лаф орабыз оруын, ныклап карасаң, әйләнә-тирәдә гел буш куык — булганнары уң йә сул оппортунистлар. Чүбек чәйнәп май язучылар. Теләсә кемнең кубызына бию шуннан килеп чыга. Гомумән, илдә фән өлкәсендәге чуарлыкка түзеп тора алуыбызга шаккатам.— Аннан сүзне кабат төп темага борды һәм инде ничәнче кат бер үк төрле сорауны бирде: — Милли кадрлар мәсьәләсе Казанда ничек тора?

— Юк дисәң дә дөрес булыр. Күбесе Вольфович кулыннан үткән, сөрсегән шәкертләр. Аерып әйтергә кирәк, Казанда Татар коммунистик университетын тәмамлаган яшьләргә шактый киң юл ачылган. Ә менә сыйнфый көрәшкә ныклы әһәмият бирелми. Татреспубликада бу мәсьәләдә күп эшләргә туры киләчәк безгә.

Сталинның йөзендә караңгы күләгәләр йөгереште.

— Кемгә? — дип сорады ул, кырыс тавыш белән.

Маленков төртелеп калды. Шулай да сүз башларга көч тапты:

— Беренче чиратта, әлбәттә, Алемасовка һәм өлкә партия оешмасына.

— Таянырлык иптәшләр бармы? Бигрәк тә яшь кадрлар белән ныгыту мөмкинлеге бармы республиканы? Хөкүмәтне кемнәр җитәкли, ТатЦИК кемнәр кулында? Алемасов дип кенә утырып булмый бит. Аңа да таянырлык кешеләрнең булуы шарт.

Кулындагы папканы ачып, Маленков, тирән тын алганнан соң, сүзен дәвам итте:

— Иптәшләр белән сөйләшкәннән соң, берничә яшь кадрга тукталдык.— Ул авырыксынып укый башлады.— Дәүләтъяров Әхмәтсафа Мостафа улы. Казанда, районнарда эшләп тәҗ-

рибә туплаган. Политэкономист. Хәзер «Кызыл Татарстан» газетасында җаваплы редактор. Халык комиссарлары советы рәислегенә исәп тотабыз. Иптәш Мөхәммәтҗанов тәкъдим итә, Алемасов каршы түгел. Республиканы аның кебек яхшы белүчеләр сирәк дип уйлыйм. Әлегә шәхси делосын тикшерү бара.

— Политэкономист... Сафсата куертучы гына булмасмы? Вольфовичка карашы ничек?

— Кызганыч, пленумда ул катнаша алмады, әллә командировкада, әллә, авырып, ялга киткән, диделәр. Әмма Вольфович Казанда контрреволюцион эшләр майтарганда, бу егет районда булган. Танышлыклары юк чамасында булса кирәк. Чөнки теге карт ишәкне энәсеннән җебенә кадәр тикшердек, Дәүләтъяров фамилиясе бер генә мәртәбә дә телгә алынмады. — Маленков, маңгай тирен сөртеп, дәвам итте. — Тагын Динмөхәммәтов дигән кеше бар. Ышанычлы, диделәр иптәшләр. Татреспубликаның Үзәк Башкарма Комитетын җитәкләрлек тәҗрибәсе бар. НКВДны ныгытуны исә Алемасов үз өстенә алды. Анда инде ул тәртип урнаштыра башлаган. НКВДны әлегә ул үзе җитәкли, киләчәктә дә ул участокка милли кадрларны кую урынлы булмас дип уйлыйм. Казан бу мәсьәләдә куркыныч шәһәр, иптәш Сталин.

Маленков, папкасыннан алып, Сталинга кәгазьләр сузды:

— Дәүләтъяров белән Динмөхәммәтовка кагылышлы мәгълүматлар, иптәш Сталин.

Генсек кәгазьләрне алып күз йөртеп чыкты да әһәмият бирмәгән тавыш белән әмер бирде:

— Казан белән эшне дәвам итегез!

Бу — кандидатураларның «үтүе» иде. Маленков бүлмәдән чыкканда сөенеп куйды. «Ярый әле, бер-ике фамилияне эләктереп кайткан. Алдан күрүчәнлек дими ни дисең. Тотты да шартлатып ышанычлы милли кадрлар турында сорау бирде менә. Ык-мык итеп торса, бетә иде. Татарстанда Алемасовтан башка бер җитәкче сайламыйча кайткансың, дип, башыңны кире кайнап торган Казанга олактырырга да күп сорамас бу Коба. Коба түгел, кобра». Аннан шундый шайтани фикернең башына китереп бәрүеннән бөтен тәне белән калтырана-калтырана аргы яктагы бүлмәсенә ашыкты: Алемасовка бүгенге сөйләшү хакында кичекмәстән шылтыратырга кирәк иде.

## V

Казанга кайтканнан соң, беренче мәртәбә ял итәргә форсат туган иде.

Маленков катнашындагы пленум көннәрендә Әхмәтсафа Дәүләтъяров, кыска вакытлы ял алып, гаиләсе белән Иделгә,

Маркиз утравындагы дачага китеп барган иде. Әллә кирәк дип санамаганнар, әллә эзләп тә таба алмаганнар (бераз тырышлык күрсәтсәләр, аны Идел буеннан табу ул кадәр кыен да булмагандыр), әмма аны эзләп килүче булмады, бер айһайсыз дип әйтерлек рәхәтләнеп ял итте алар монда. Дача хөкүмәт исемлегендә булганлыктан, ашау ягы да ярыйсы, ял итәргә дә мөмкинлекләр җитәрлек иде.

Моңа Рабига сөенеп туя алмады. Уллары Марат белән Марлес көнозын саф һавада, янында кадерле ире, Казанда барган хикмәтләр монда килеп ирешми дип әйтерлек, хатын-кыз тансыклаган тынычлык, татулык хөкем сөрә иде. Тагын ни кирәк үзеңне бәхетле тояр өчен?! Берни дә кирәкми, менә шушы көннәрнең ямен җибәрерлек хәлләр генә була күрмәсен! Яр буендагы аксыл комда, җылы рәхәтлектә оеп ятканда шулай уйлады Рабига. Шулай уйлап бетермәде, һич тә булмаганча, йөрәген нидер сызып үтте, Казанда соңгы вакытларда һич ташлап китмәгән күңелдәге шом терелде. Кечкенәдән әнкәсе Хәлимәтти өйрәткән догаларны эчтән укый башлады. Күзенә яшь бөртекләре бәреп чыкты, Рабига догалар пышылдавын кемдер сизеп-ишетеп тормасын дигән уйдан сикереп торып утырды. Көннең яме бераз кителде сыман. Нинди сәбәп бар, нигә болай тынгысызлана бүген? Бу хакта уйларга да тартына, бары тик йөрәге урыныннан купты да куйды менә. Хәзер кичергән августның соңгы көннәрендәге иләс рәхәтлек яңадан кире кайтмас шикелле тоелды аңа. Ул тирә-ягына каранды. Якында гына ике марҗа кызынып ята, аларның бер кешедә кайгылары юк, йөзләренә газит кисәге япканнар, сөйләшеп ардылар бугай, бар байлыкларын таратып ташлап, гырлап йокыга ук киттеләр, ахры. Рабига, тынычланып, карашы белән ярдан шактый ераклашып көймәдә йөзгән ире белән улларын эзләп тапты. «И Ходаем, шушы бәхетемне, гаилә иминлегемне күпсенә күрмә!» — дип пышылдады ул ирексездән. Керфек очларына янә яшь эленде. Ул сикереп торды да көймәдәгеләргә кул болгарга тотынды. Үзе һаман авыз эченнән: «Кайтыгыз, кайт, наныйларым, миңа монда ямансу, бер генә минут та сездән башка торасым килми»,— дип кабатлый иде.

Әхмәтсафа, хатынының ашыгып-ашыгып кул болгавын күреп, көймәне ярга табан борды. Марат, көйсезләнеп, ишкәкләргә ябышты. Аның һич тә кире борыласы килми иде.

— Ярга борма инде көймәне, йөрик әле, әтием, тагын! Әйһәй оста, безне алдау өчен генә көймәгә утыртып су эченә керде дә кире чыгарга маташа. Яңа кердек бит Иделгә,— диде ул үҗәтләнеп.— Марлес, кил, мешайть итеш миңа! — дип, куркыбрак утырган энесенә әмер бирде. Бу Хәлимәтти сүзләре, ул үзенә булышам дип, эшенә кыенлык тудырып

мәшәләнүче оныкларына көлеп: «Һи, улыкайларым, үсеп тә җиттеләр, миңа ныклап мешайть итешәләр бит», — дия иде.

Мышкылдый-мышкылдый Марлес та икенче ишкәк сабына тотынды. Шулай көлешә-көрәшә ишә торгач, көймә борынын ярга китереп төртте.

Әхмәтсафа абайламый да калды, болан тизлегендә көймә эченә Рабига сикереп керде, үпкәләгән тавыш белән:

— Миннән башка гына йөрмәгез әле! Мине дә алып керегез Иделгә! — диде.

Хатынының күңеле тыныч түгеллеген сизеп алды кебек Әхмәтсафа.

— Нинди шөпшә чакты сине, карчык, — диде, шаяртырга теләп.

Рабига эндәшмәде. Карашын Идел киңлекләренә төбәп торды, аннан алдында утырган Марлесның башына кояшта яна төшкән битен терәде һәм астан гына Әхмәтсафага күз сирпеде. «Берни дә сорама, иш кенә» дигән сыман иде бу серле караш.

Озак йөзделәр алар, төшке ашка кадәр Иделдән чыкмадылар. Ишкәк ишкән саен, Әхмәтсафа үзендә көч артканын тоя, Рабига исә улларына сыенып утырган да иренең гайрәтле беләкләреннән күзен алмый. Ни уйлый ул, ни дип тынгысызлана болай, Әхмәтсафа һич аңлый алмады. Хәер, җан халәтен аңа Рабига үзе дә аңлатып бирә алмас иде...

...Казандагы үзгәрешләр хакында аңа нәшриятның тәрҗемә бүлегендә эшләүче Сәхиб Мирзаханов әйтте. Сәхиб белән дуслар иде алар, серләре килешә иде. Мәгълүматларны кемнән ишеткәндер, бәлки, Әхмәров пленумнан соң ук Сәхибне Әхмәтсафа янына махсус җибәргәндер, ярты гына көнгә, һава алырга килдем, диде үзләре янына дачага килгән Мирзаханов. Алемасовның Беренче итеп сайлануына әллә ни исе китмәде аның. Эшләр шул якка барганын аңламас дәрәҗәдә түгел ул, ә менә үзенең шушы пленумда ӨК комитеты әгъзасына кабат «күтәрелүенә» гаҗәпләнде дисәң дә ярый. Бу биеклектә сакланып кала алуның астында нәрсә ята — аңа караңгы иде.

— Мине хәтта анда чакырып та тормадылар, — диде ул, Идел ярының аулак почмагында Сәхиб белән икәүләшеп сөйләшеп утырганда. — Минем өчен аптырарлык хәл дип әйтимме... Шундый катлаулы чор бит.

— Анысы инде миңа караңгы, дускай. Бары тик бу сыйфатта сине тәбрик кенә итә алам. Безне танымыйча китмәссең бит, очрашкан чакларда дим. — Сәхиб көлеп җибәрде. Ул тыйнак Дәүләтъяровның борын чөеп йөрүен үзенчә күзаллап карады, ахры.

— Рәхмәт, — диде Әхмәтсафа, саран елмаеп. — Үзең читкә карап үтмәсәң, без инде алай кеше танымас хәлгә җитмәбез...

Сәхиб ничек тиз килсә, озак юанмый китеп тә барды. Инде җанны тынычсызлык биләп алган иде. Икенче көнне Әхмәтсафа да Казанга әйләнеп кайтты. Рабиганы ул биш көннән соң гына килеп алды.

...Вакыйгалар агышына бәя биреп бетермәле түгел иде. Озакламый республикада иң абруйлы җитәкчеләрнең берсе – Кыям Абрамовның «халык дошманы» икәнлеге мәгълүм булды, аның артыннан Гомәр Байчурин исемен телгә алмый башладылар. Ул да «дошман» икән.

Сентябрьнең унҗидесендә, кичкырын аны Алемасов өлкә комитетына чакыртып алды. Көтмәгән иде, каушап килеп керде Беренченең бүлмәсенә. Анда Алемасов белән бергә Мөхәммәтҗанов та утыра иде.

Кул биреп күрештеләр.

— Утыр, иптәш Дәүләтъяров... Хәлләр ничек? Сөйләп җибәр.— Алемасов кемнәндер сорау алгандай тотты үзен.

Тәнендә җиңелчә калтырану тойды Әхмәтсафа. Кабинетта салкынча, шуңамы, тәненә каз йоннары төртеп чыкты. Ул ялт итеп Мөхәммәтҗановка караш ташлады. Тегесе тыныч кына утыра иде.

— Рәхмәт, иптәш Алемасов. Редакция эшли. Партия установкаларын...

Алемасов аны кул хәрәкәте белән туктатты.

— Әйдә, ачыктан-ачык сөйләшүгә күчик. Без иптәшләр белән киңәштек монда... Алар каршы түгел...

Шунда гына Мөхәммәтҗанов күтәрелеп Әхмәтсафага карады. Үзеңне ышанычлы тот дигәндәй, җиңелчә генә күз кысып алды.

— Аңлап җитмим, иптәш Алемасов,— диде Әхмәтсафа, кыюлана төшеп.

— Менә мин дә аңлап җитмим әлегә. Иптәш Мөхәммәтҗанов, син үз фикереңдә каласыңмы? — Беренче, тапкыр сүз әйтүенә куанган төсле, авызын ерып алды.

Галим урыныннан сикереп торды.

— Әйе, иптәш Алемасов, мин Дәүләтъяров кандидатурасын яклыйм һәм аңа тулысынча ышанам.— Сүзен әйтеп бетермәстән, шап кире урынына да утырды.

— Алайса, серне үзенә генә чишәргә дә ярый торгандыр. Сиңа, иптәш Дәүләтъяров, тагын да җаваплы вазифа тәкъдим итәргә булдык...

Әхмәтсафа куырыла төште. Чигә төшкән баягы калтырау янә кайтты. Ул, Беренченең дәвам итүен көтеп, тын алмыйча утыра. Тынлык озаккарак сузылды. Әхмәтсафа кызарып чыкты. Тагын яңа эш, тагын күченү булыр микән инде?..

— Халык комиссарлары рәисе вазифасы буш тора. Син тарта алырсың дип уйлыйбыз...

— Кәнишне, тарта,— диде Мөхәммәтҗанов.— Иң хәзерлекле кешебез ул безнең...

Үгетләп тору булмады. Яңа вазифага ризалык та сорап тормадылар. Бары инде эш хәл ителгән дип санаган Алемасов, бер мәзәк сөйләп алуны кирәк дип тапты.

— Кирмәнчектә эшләгәндә бер иптәшне җаваплы вазифага кыстыйм. Ялындырып маташа. «Хатыннан сорап килим әле»,— дигән була. Күзләреннән күреп торам, урын җилле, эшне ычкындыру ярамый, егылып киткәнен дә белгертәсе килми. «Ярый,— дим,— бар, сорап кил»,— ачуланганны сиздермим тегеңә. Ялындырып торырга проститутка түгел бит инде. Мужик бул, хатыннан рөхсәт сорый, имеш... Ике көннән соң килде. «Хатыныңнан сорадыңмы, нәрсә диде?» – дип каршы алдым. «Сорадым, хатын риза», — ди инде бу. «Мин дә хатыннан сорадым синең хакта. Минем хатын риза түгел», — дигәч, күзен шар итеп карап тора теге. Куып чыгардым кабинеттан.

Барысы да көлешкән булдылар...

...Беренче бүлмәсеннән ул ялгыз гына чыкты. Мөхәммәтҗанов Алемасов янында калды. Әхмәтсафа уйларын тәртипкә китерергә теләп, акрын гына нәшрият ягына атлады. Аңа бу сөйләшү хакында серне беркемгә дә чишмәскә кушылды, иртәгәсе көнне инде җаваплы постка рәсми рәвештә раслау булачак иде. Аның язмышына кагылышлы вакыйгалар шулхәтле тиз үзгәрә, яхшыгамы бу, ямангамы, чамалап та бетерми. Яңа эшкә тәкъдим итәләр, ул анда ияләшеп тә өлгерми, тагын бер вазифа әзерләп куйган икән аңа Язмыш дигән абзый. Яңа эшкә билгеләгәндә сүз иң элек фирка исеме белән башланганга күрә, ул тәкъдимне кире кага алмый, рухы белән карышып, газаплана-газаплана риза була, тик эчке халәтен башкаларга сиздермәскә тырыша. Моны Рабига гына сизә, яңа эшкә күчәргә тиешлеген белгәч, ничектер, йөзенә курку билгеләре чыга. Ниндидер куркыныч хәлләрнең якынайганын сизенгән кебек, шомланып иренә карап тора. Рабиганың шушы карашын күтәрүе авыр Әхмәтсафага.

Өлкә комитетыннан чыгып, редакциягә әйләнеп кайтканчы күз алдыннан соңгы елны янә тулысынча үткәреп алды. Язмыш кайсы якка әйдәкли аны?.. Тырышып шушы сорауга җавап эзләде, әмма җавап таба алмады. Барысы да шома, чиста барган сыман, хәвефләнерлек сәбәп тә юк кебек. Шулай да гадәти чорда яшәмәү һәрдаим үзен сиздереп тора. Ниләр кичерде соң ул Казанга кайтканнан соң?

...Үткән елның гыйнварыннан — май аена кадәр ул Татарстан дәүләт китап нәшриятында сәяси әдәбиятны тәрҗемә итү бүлегендә эшләде, озак та үтми Таттосиздатның баш редакторы һәм партоешмасы сәркатибе итеп билгеләнде. Аны

бу эшкә Галим Мөхәммәтҗанов белән Әхмәров димләгән иде. Нәшриятта эшләгән һәм соңыннан «халык дошманы» буларак кулга алынган Исхак Рәхмәтуллин, Сәлах Әтнәгулов, язучы Сәйфи-Казанлы, өлкә комитетында пропаганда бүлеген җитәкләгән Зәки Гыймрановлар да аны яклаганнар иде. Нәкъ шушы кешеләрне «халык дошманы» дип кулга алып, төрмәгә утырттылар. Ул көннәрдә Әхмәтсафаның йокысы качты, һәркөн диярлек күрешеп, хәл-әхвәлләрне сорашып йөргән кешеләр, үзара гәп корганда нинди генә сүзләр ычкынмый авыздан, кем уйлап тора аны, шушы уйнап-шаярып сөйләшүләрдән кемдер дошманлык китереп чыгарса?..

ТКУда, аспирантурада үзенә белем биргән профессорлар Николай Эльвов, Тимофей Ищенко, Василий Слепков кулга алындылар. Өлкә комитетының икенче секретаре Бари Абдуллин да «халык дошманы» булып чыкты. Аның урынына Галим Мөхәммәтҗанов сайлангач, элекке «яшьләр комиссары», башкаларның гыйбрәтле язмышын кабатламаска омтылып, тиз арада үз даирәсен ныгыту эшенә тотынды, ягъни бу шомлы елларны исән-имин хәлдә үткәреп җибәрү нияте белән ныклап уйланылган чаралар күрә башлады.

Кулга алынган кешеләр истән бер генә көнгә дә чыкмый дисәң дә була. Әхмәтсафа әлеге кешеләрнең намуслы, тырыш журналистлар, булдыклы хезмәткәрләр икәненә дә иманы камил, әмма шундый көннәр килеп җитте — һәркем үзенең шәхси куркынычсызлыгы хакында гына уйлый. Беркемнең беркемдә эше юк — кулга алалар, булдыклы кадрларны эштән, партиядән куып чыгаралар, гаебе бармы бу кешеләрнең, юкмы, уйлап торырга вакыт юк, бер-берсе белән ярыша-ярыша аларның өстенә ләгәне белән пычрак коялар, әле кичә генә дуслашып, кунакка йөрешкән кешеләрнең шулкадәр ямьсезләнүләрен Әхмәтсафа инде аңлый да аңлата да алмый. Сталинның «Социализм чорында сыйнфый көрәш тагын да көчәя» дигән сүзләрен дога итеп ятлаган эрелеваклы түрәләр, калдык-постык интеллегенция әһелләре (зыялы дип хөрмәт белән телгә алырдай олуг затлар күптән кулга алынып сөрелгән, юк ителгән, яисә төрмә шулпасы хисабына җан асрауда иде) кем күпме булдыра ала, шуның кадәр сыйнфый көрәш учагына үз утынын ыргытып калырга, шуңа бәрабәр үзенең тормышын сакларга тырыша иде.

Әхмәтсафага НКВД тозагына эләккән кешеләрне төрлечә газаплаулары, җәзалаулары хакында да хәбәрләр ишетелгәли. Билгеле, бу хәбәрләр иң ышанычлы кешеләргә, үтә аулак урыннарда сер итеп кенә әйтелә, ишеткән кеше бу серне күңел сандыгына бикләп куя да, керпе кебек җыелып, үз эчендә бикләнеп, курку-шом эчендә яшәвен дәвам итә. Тоткыннарга физик тәэсир итү яки, гади генә әйткәндә, җәзалаулар Үзәк Ко-

митетның яшерен күрсәтмәсе нигезендә алып барылганын да белә ул. Күпләр белә, әмма беркем дә дәшми. Дәшмәү — алтын дигәнне тулысы белән аңлый башлады халык.

Беркөнне Әхмәтсафа өенә кайтып чишенеп өлгермәде, каршысына Рабига атылып килеп чыгып колагына пышылдады: «Бүрәнә башы тишек!» Үзе күзен-кашын уйнатып, әлеге сүзләрнең мәгънәсен аңлатмак була. Түргә үтсә шул билгеле булды, йомыш табып күрше хатыны килеп кергән икән дә, кайткан уңайга ире әллә нәрсәләр такылдап ташламасын дип, Рабига аны кисәтергә чыккан икән.

Ил өстендә шом, һәркемнең баш очында кара болыт шәүләсе, һәркем үз янәшәсендә ниндидер күләгә әйләнгәләп-тулганып йөрүен белеп, тоеп тора. НКВД үрмәкүч пәрәвезе сыман бөтен яшәешне чорнап алды. Аз гына селкенсәң, күзгә күренмәс җеп тартылып куя, тирә-юнеңдә ниндидер шикле хәрәкәт барлыкка килүен сизеп, тын кысыла, йөрәккә суык йөгерә.

«Кызыл Татарстан» газетасына җаваплы редактор итеп билгеләнгәч, аны Галим Мөхәммәтҗанов чакыртып алды. Әхмәтсафаның бу эшкә авырлык белән риза булганын яхшы белгән Галим аны үгетләргә теләде булса кирәк.

— Хәзер телим-теләмим дигән сүзләр, партия тәкъдиме хакында озаклап уйланулар, тәкъдимгә каршы төшү кебек күренешләр бетте бит ул, иптәш Дәүләтъяров,— диде ул, яңа редакторга сүрән карап.— Бармак очы кемгә килеп төртелә, шул минутта бу бәндәнең язмышы да хәл ителә. Йә ул дус, йә — дошман.— Мөхәммәтҗанов сүзен әйтеп бетермәде, кабинет түренә элеп куелган Сталин сурәтенә борылып карап алды һәм корыч тавыш белән сөйләвен дәвам итте.— Әйе... Кадрларны ныгыту, булдыклы кешеләрне барлау, аларга җаваплы эшләрне ышанып тапшыру кебек мөһим мәсьәләләр хәл ителә бу көннәрдә. Кадрлар барысын да хәл итә! Син безнең кадр, иптәш Дәүләтъяров, партия солдаты.— Ул, урыныннан торып, Әхмәтсафаның каршысына килеп басты.— Беләм, беләм, син дә йоклап ятмыйсың. Информация җитәрлек синдә.— Галим, сер сөйләгәндәй, пышылдауга күчте.— Яшермим, синең кандидатура җиңел генә үтмәде. Бигрәк тә Абрамов белән Байчурин каршы килделәр. Журналист түгел дип, аяк терәп карыштылар, ну мин булдыра алганча аңлаттым. Ризалашмый хәлләре юк. Беләләр минем мәңге икенче булып йөрмәсемне.— Ул, күз кысып, Әхмәтсафаның җилкәсенә кулын салды.— Алда эшләрнең очы-кырые юк, уңнысулны карамыйча алга, алга! Девиз шул безнең. Киләчәк, ышанып әйтәм, безнең кулда! — Ул уфтанган кебек әйтеп куйды.— Жәл, синең белән иркенләп сөйләшү иде теләгем, барып чыкмады, мине Беренче үзе көтә,— дип, ашыгып Әх-

мәтсафага кулын суздь. — Иптәш Ежовның сүзләрен онытма: «Безнең илдә население өч категориягә бүленгән: беренче категория — гаепләре ачылып, хөкем ителгәннәр, икенчеләре — тикшерүдәге тотаклар, өченчеләре — шиклеләр», — ди ул. Шәп әйтә бит, ә?! Менә бу коммунистларча! Турыдан яра тимер нарком. Минем уемча, без өченче категориягә якын кешеләр... Суга кергәч, коры чыгып булмый, аңлыйсың. Без инде суның уртасында. Нык куллы бул, җебеп торма!

1937 елның егерменче июнендә Татарстан партия оешмаларының унсигезенче өлкә конференциясендә Әхмәтсафа Дәүләтъяров өлкә комитеты әгъзасы итеп сайланды. Исемлектә ул егерменче кеше иде...

Конференция бигрәк тә матбугат эшен оештыруга әһәмият биргән карар чыгарды.

«Партия җитәкчеләренең матбугатка кырын карауларын тәмам бетерергә, матбугатта партия җитәкчелеген яхшыртырга.

Газеталарның идея-политик дәрәҗәләрен югары күтәрергә, партия тормышы һәм партия төзелеше мәсьәләләрен яктыртуны көчәйтергә, газета битләрендә үзеңне тәнкыйтьләүне генә җәелдерүне тәэмин итәргә, масса белән бәйләнешне көчәйтергә, редакциядән тыш автор кадрлар белән эшләүне оештырырга кирәк».

Конференциядә катнашучылар еш кабатланган «Политиканы хуҗалыктан аерырга ярамый. Без политикадан китә алмаган шикелле үк хуҗалыктан да китә алмыйбыз» дигән даһи фикернең асылын аңларга тырышып, илаһи бер әсәрләнү кичереп утырдылар. Бу сүзләр Сталинныкы иде һәм бу кадәр дә гади нәрсәне гениаль дәрәҗәдә катлаулы итеп ул гына әйтә ала иде.

Конференция Альфред Карлович Лепаны кабат өлкә комитетының Беренче секретаре, «халык дошманы» буларак кулга алынган Бари Абдуллин урынына Ленин-Сталин юлыннан тайпылмый баручы Галим Мөхәммәтҗановны икенче секретарь итеп сайлады һәм икенче көнне үк Әхмәровка Дәүләтъяровны чакыртып, газетаны аның кулына тапшырырга боерды.

Утыз җиденең егерме икенче июнендә «Кызыл Татарстан» газетасының йөз дә кырык икенче санына инде җаваплы редактор тамгасын Әхмәтсафа Дүләтъяров салды. Моңа кадәр җаваплы мөхәррир вазифасын башкарган Исхак Еникеевны ул күреп тә өлгермәде...

Нинди көннәр иде ул!

...Илдә, бер яктан карасаң, шом, шик-шөбһә тулып ята, икенче яктан алсаң, иләслек, күтәренкелек хөкем сөрә — шушы көннәрдә генә Мәскәү — Төньяк Котып — Америка Кушма Штатлары маршруты буенча туктаусыз очыш тәгәлләнгән иде. Үзе

беренче мәртәбә кул куеп чыгарган газета тулаем дип әйтерлек шушы очышта катнашучыларны зурлауга корылган иде. Беренче битнең башына зур хәрефләр белән: «Бөтендөньяны таңга калдырган геройларыбызга — Чкалов, Байдуков, Беляков иптәшләргә ялкынлы большевистик сәлам!» — дип язылган сүзләргә Әхмәтсафа озаклап карап торды.

Шунысы сәер — күңелендә соклану хисе юк иде. Җанын нидер бимазалый. Берәр ялгыш китмәгәнме, беренче эшеннән үк гаеп, хата табып, адәм хурына калдырып редакциядән куып чыгармасलармы? Күңелдә шушы сорау, күз алдында үзен кая куярга белми бәргәләнүче Рабига...

Газетаның бу саны басылган төнне ул типографиядән чыкмады да. Басу машиналары тавышы, буяу исе торган саен аны исәңгерәтә, менә хәзер генә нидер килеп чыгар да бөтен эш туктап калыр, барысы да аңа, бармак төртеп, «дошман, дошман...» дия-дия такмаклар кебек. Типография эшчеләре яннарына килеп баскан яңа редакторга кырын карап алалар. Әхмәтсафа мондагы кешеләрнең бер-берсенә ышанычларының тәмам югалганын, беткәнен аңлап, тәненә суык йөгерде. Ерак Бохарада, чит-ятлар арасында йөргәндә дә, бу кадәр ялгыз тоймады ул үзен. Бүген исә ул ялгызлык хисенең нәрсә икәнен үз җанында татыды. Барысы да хата-мазар китмәсен дип курка монда, инде хата китеп, ул дөньяга фаш була икән, җавап бирүче берәү булачак: ул кеше — Әхмәтсафа Дәүләтъяров... Котыпчыларны юлбашчы Сталин, аның тугрылыклы дуслары Молотов, Ворошилов, Каганович, Калинин, Жданов, Ежов, Микоян, Андреев котлаган. Аларны укыйукый күзләре талды Әхмәтсафаның, инде газетаның сынау саны кулга кергәндә, күз алдында хәрефләр биешеп, ни укыганын аңламас хәлгә җитеп килә иде. Бераз ял итеп алгач, янә бер мәртәбә укып чыкты, хаталар юклыгына ышангач, тынычланып калды, иң мәзәге шул, хәтта берзаман иңнәренә канат үскән сыман булып, шушы геройлар белән бер чорда яшәвенә сөенеп туймыйча, үзен бик-бик бәхетле итеп сизә башлады.

Өенә таң алдында гына кайтып җитте ул. Аны Рабига куркулы караш белән каршы алды... Хатынының күзендә чагылган курку Әхмәтсафаның төшенә керә башлады. Рабиганың вакыт-вакыт ниндидер өметсезлеккә бирелүе һич тә охшамый иде аңа.

* * *

Җаваплы редактор вазифасына керешкәч, кулына килеп кергән беренче истәлекле хат Мәскәүдән, Муса Җәлилдән иде.

Муса газетаның җаваплы редакторы итеп Әхмәтсафаның билгеләнүен белсә дә, хатны артык рәсми язган. Күрәсең, моннан алдарак, ягъни август башларында газетада чыккан

Сәгыйтов хаты аны шактый хафага салган һәм бу хатның дөнья күрүендә яшьлек дусты Әхмәтсафаның да гаебе бар сымаграк хис иткән.

*Иптәш редактор!*

*Шушы хатны газетада басып чыгаруыгызны сорыйм: «Кызыл Татарстан» газетасының 1937 ел 10 августта чыккан 183 нче номерында Ф. Сәгыйтовның (хат авторының фамилиясе үзгәртелеп бирелә.— Автор) «Татар операсы студиясе турында» дигән мәкаләсе чыкты. Бу мәкалә нигездә Татар опера студиясенең эшләрен дөрес тәнкыйть итә һәм җитәкчелек тарафыннан җибәрелгән хаталарны, җитешсезлекләрне, төбендә, дөрес фаш итә. Шунлыктан студиянең эшен яңабаштан коруда, аның җитешсезлекләрен бетерүдә бу мәкалә уңышлы роль уйнаячак.*

*Ләкин мин мәкаләдә минем исемем белән бәйләп язылган кайбер юлларга карата түбәндәге төшендерүне биреп үтәргә үземне бурычлы саныйм:*

*Ф.Сәгыйтов үзенең мәкаләсендә минем тарафтан язылып ята торган кайбер әсәрләр турында: «М.Җәлил иптәш «Алтынчәч», «Балыкчы кыз»ны яза, ләкин... алар бүгенге көн сорауларына җавап бирерлек булмыйлар»,— ди. Аннан: «... аның (Төхфәтуллинның.— М.Җ.) биргән темалары да үзләренең исемнәре һәм эчтәлекләре белән бераз уйга калдыралар»,— ди дә, шул әсәрләр арасында «Балыкчы кыз» белән «Алтынчәч»не күрсәтеп, түбәндәге юлларны өсти:*

*«Болар бүгенге көн продуктлары булудан бигрәк, совет эшчеләр сыйныфы тарафыннан җимерелгән иске тормышның үлем алдында, актыккы сулышларын алганда хыяллану нәтиҗәсендә туган «җимешләре»нә охшыйлар».*

*Башлап «Балыкчы кыз» турында:*

*«Балыкчы кыз» әле минем тарафтан язылып беткәне юк. Шунлыктан беркая да тапшырылганы да, бер җирдә дә укылганы да, тикшерелгәне дә юк. Бары үткән ел студия каршындагы бер киңәшмәдә аның планы гына тикшерелде һәм, төбендә, темасы, сюжеты ярарлык табылды. Ләкин бу әсәрне язу өчен минем бер оешма белән дә договор төзегәнем һәм акча алганым юк. Аны язу минем иҗат планына керсә дә, төрле сәбәпләр белән әле язып бетергәнем юк. Шулай булгач, Ф Сәгыйтов бу әсәр белән бөтенләй таныш түгел. Тик аның исемен генә ишетеп белә.*

*Бу әсәрнең темасы шуннан гыйбарәт: 1933 елда Каспий һәм Волга буйларындагы балыкчы колхозларында сыйнфый дошман калдыклары чираттагы путинаны өзәргә, балыкчы ударникларны коралсызландырырга маташалар. Ләкин батыр балыкчы колхозчылар, аларны фаш итеп, путина планын ударникларча үтиләр.*

*Минем беләсем килә: ни өчен балыкчы колхозларындагы сыйнфый дошман калдыкларына каршы көрәшне чагылдырган әсәр «бүгенге көн соравына җавап бирми» һәм ни өчен аны язу «җимерелгән иске тормышның үлем алдында, актык сулышларын алганда хыяллану нәтиҗәсендә туган «җимешләре»нә охшый» икән? Кайчаннан бирле совет язучысы өчен балыкчылар колхозындагы тормышны чагылдыру хурлыклы, оятлы эшкә әйләнде?*

*Билгеле, Ф.Сәгыйтов монда әсәрнең исеменә карап кына хөкем йөртә. «Балыкчы кыз» дигән исем аның күңелендә шик тудырган да, ул әсәр язылмас борын алдан җавапсыз чыгыш ясап, авторга политик ярлык ябыштырырга тырыша.*

*Инде «Алтынчәч» турында. Бу әсәр ханнарга каршы үзенең ирекле йорты өчен көрәшкән халык батыры турындагы борынгы халык әкиятенә нигезләнгән. Дөрес, либреттоның беренче вариантында күп кенә кимчелекләр бар. Аларны рецензент иптәшләр дөрес күрсәттеләр. Ләкин аның турында бер җирдә дә бөтенләй кире кагып карар чыгарылганы юк. Киресенчә, аны төзәтергә куштылар. Ашыгыбрак язылу аркасында, анда тарихи чорларны саташтыру, образларны җанлы һәм тирән эшләмәү, халык (масса)-ның ролен ачык күрсәтмәү, либретто өчен артык озын язу кебек кимчелекләр киткән. Аларны төзәтеп, ныклап эшлисе бар. Әсәрнең язылу процессында (беренче вариантларында) бик эре хаталар булырга мөмкин. Иптәшләрчә тәнкыйть һәм рецензияләр шуларны төзәтергә, әсәрне тулы, дөрес язып тәмамларга ярдәм итәләр.*

*Ләкин ни өчен халык батырлары турындагы халык әкиятләрен (гомумән, халык әкиятләрен) тема итеп алып эшләү совет язучысы өчен хурлыклы булырга тиеш? Кайчаннан бирле безнең өчен халык иҗаты, халык әдәбиятының бай, матур темалары ят һәм дошман булдылар? Бу бит ачыктан-ачык авербахчы-таппчыларның күптән читкә кагылган «сулагай» карашлары!..*

*Монда да, билгеле, Сәгыйтовка исем ошамаган. Ул халык әкиятенең исеменнән үк өркеп, тизрәк РАПП «тәнкыйтьчеләр»енчә ярлык тагарга ашыккан. Болай булгач, Ф. Сәгыйтов совет язучысы Алексей Толстойның «Петр I» дигән романының исеменә ничек түзә икән? Патшаның исеме ләбаса!*

*Казах, Грузия, үзбәк музыка театрлары Мәскәүгә килеп, үзләренең борынгы фольклорына нигезләп язылган «Кыз Җефәк», «Даиси», «Әбүсәлам һәм Этери», «Фәрхад һәм Ширин» кебек матур әсәрләрен күрсәттеләр һәм хөкүмәт әгъзалары, Мәскәү хезмәт ияләре тарафыннан*

*алкышлап каршы алындылар. Борынгы халык әкиятләренә, тарихи темаларга, матур исемнәргә «сулагай» кизәнергә ярата торган безнең «тәнкыйтьче» бу хәлгә ничек чыдап тора икән?..*

*Шул ук мәкаләдә тагын «хәзер «Югалган шатлык»ка язылган музыкага яңа эчтәлек язу директор тарафыннан М. Җәлил иптәшкә тапшырыла...» диелгән. Бу шулай ук нигезсез гайбәт. Мин «Югалган шатлык»ка яңа эчтәлек бирергә һич җыенганым юк. «Югалган шатлык» турында минем фикерем тиешле документларда әсәр кулга төшкән моментта ук әйтелгән.*

*Мин һәм композитор З.Хәбибуллин атаклы шагыйрь М.Гафуриның «Кара йөзләр» дигән әсәрен либретто итеп эшләү турында уйлаштык һәм рецензиягә тәкъдим ясадык.*

*Һәркемгә билгеле, М.Гафури белән Ф.Бурнаш икесе ике кеше (бәлки, моны Сәгыйтов кына белми торгандыр). «Кара йөзләр» дигән әсәрнең тик Бурнашка һичбер төрле мөнәсәбәте юклыгын һәркем белә. (Директорның миңа беркайчан да тема биргәне юк.)*

*Мин уйлыйм, һәрбер либреттист һәм композиторның атаклы совет язучыларының танылган әсәрләрен музыкага яраштырып эшләргә хаклары бар.*

*Ф.Сәгыйтов бу мәсьәләләрдә тикшермичә, нигезсез һәм җавапсыз чыгыш ясап, безнең алдагы эшебезгә кара ыргыта.*

*Югарыда күрелгәнчә, Ф.Сәгыйтов мәкаләсенең бу өлешен тикшермичә, коры гайбәткә, ишеткән сүзләргә һәм исемнәргә таянып язган. Мондый җавапсыз «тәнкыйтьләр» язучыга һичтөрле файда бирмиләр. Мәкалә түбәндә опера студиясенең хаталарын һәм җитешсезлекләрен дөрес тәнкыйтьли һәм, һичшиксез, мин, студиянең бер җаваплы эшчесе булу сыйфатым белән, ул хаталар, җитешсезлекләр өчен үземне җаваплы саныйм.*

*Сәлам белән М. Җәлил».*

...Сәгыйтов зур эш эшләгән кыяфәттә аның алдына «Татар операсы студиясе турында» дигән, нигездә, тәнкыйть рухында язылган һәм бигрәк тә Муса Җәлилнең иҗатына тап төшерү нияте әллә каян күренеп торган мәкаләсен җаваплы редакторның эш өстәленә кертеп салган көнне яхшы хәтерли Әхмәтсафа.

Эше тыгыз чак иде. Сәгыйтовның һич чыгып китәргә җыенмавын сизеп:

— Утырып тор дисәм, хәзер типографиягә йөгерәм, кайтып кергәнемне көт дисәм... — дип сүз башлаган иде, аны Сәгыйтов кырт туктатты.

— Мәкаләне хәзер үк укып чыгуыңны көтәм, иптәш Дәүләтъяров. Эшем чикләвеге булып кыланмасаң да була. Газета язмышы без — журналистлар кулында ул. Синең чабулап йөрүеңнән әллә-ни өре чыкмас, ә мин сиңа моңарчы күтәрелмәгән тема алып кердем. Тиз генә күз йөртеп чык та, әллүр, санга урнаштыру чарасын тап. Мәсьәлә үтә дә мөһим, көтеп торышлы түгел, сүз татар сәнгатенә хас кимчелекләрне вакытында күрсәтеп, ул җитешсезлекләрне кичекмәстән төзәтү турында бара! — дип кайнарланып, чәпчеп алды.

Сәгыйтовтан болай гына ычкынып булмасын аңлаган Әхмәтсафа мәкаләне ашыкмыйча укып чыкты һәм бертын уйга калды. Сәгыйтов үз амплуасында — талантлы чордашларын фаш итү белән шөгыльләнә.

— Җитди... нәрсә бу... Муса нәрсә дияр бит...— диде көттереп кенә Дәүләтъяров.

Сәгыйтов канәгатьләнеп урындык артына ава төште.

— Минем юк-бар язмаганга инде бишбылтыр Сафа. Муса, башында акыл булса, рәхмәт әйтер. Миңа нәрсә, язган, беткән, калганы аның үзеннән тора. Обыватель баткаклыгыннан чыга алса, кеше булыр, көченнән килмәсә, яңадан андый мөһим эйбергә кагылмаслык итәрбез... Сиңа яңалык бу кәнишне. Ләкин безнең һөнәр шуны таләп итә. Ну, эш барышында үзең дә аңларсың. Муса бүген дус, иртәгә чуртым белсен — кем ул? Вакытында кисәтеп кую зарар итми безнең эштә.

— Муса хакында алай уйларга ничек батырчылык итәсең, Фатыйх. Безнең белән бергә үскән, язмышның бар җәберен кечкенә иңнәрендә күтәреп тә бирешмәгән, тырышлык, иҗтиһат итү аркасында мәртәбәләргә ирешкән дустыбыз ич ул.

Сәгыйтов, калын иреннәрен чалшайтып, аның сүзен бүлдерде.

— Шыттырма, иптәш Дәүләтъяров, Муса белән дә, башкалар белән дә дус булмадым. Мин һәрнәрсәгә сыйнфый күзлектән карыйм. Үземә җавап тота торган кеше мин, башкалар өчен җавап тотып, тинтерәп йөрисем килми.

— Шулайдыр, тик мәкаләне ашыктырмыйк. Мусага, яңа аяк басарга азапланган татар опера студиясенә болай кизәнү... Ахыры хәерле бетмәскә дә мөмкин бит, нинди чорда яшәгәнне онытма!

Сәгыйтов сикереп торды, ачулы күзләренә кан йөгерде.

— Нинди чорда яшибез димәкче әле син? Син, нәрсә, минем белән малай-шалайлы уйнап утырган буласың? Мин Татарстанның әйдәп баручы журналистларыннан берсе.— Сыңар кулының бармакларын уйната-уйната Әхмәтсафага сузды.— Без менә күпме андый абруйлы, журналистиканы тотып торучы каһарманнар, аңладыңмы? Ике-өч и обчелся. Син гәзит эшендә әлифне таяк дип белмисең. Артыңнан төр-

теп йөрүче булгач... утырасың инде җан көеге булып. Бу синң Дәүләтъяров Иске Байсар авылы идарә йортыннан кулак бичәләрен куып тарату түгел, катлаулы мәсьәлә. Моңа башың җитми синең, шуңа куркасың бастырып чыгарырга. Ашыгыргамы, ашыкмаскамы, анысын сиңа караганда мин яхшырак беләм.

— Энәдән дөя ясама, Сәгыйтов! Мин әле журналистларга тел-теш тигезгәнем юк.

Әхмәтсафа, сабырлыгын җуймаска тырышып, бу чик-чаманы белмәүче бәндәне акылга китерергә азапланган арада, Сәгыйтов өстәлдә яткан мәкаләсен шатырдатып тартып алды да каты басып чыгып китте.

— Беләм мин сине...— диде Сәгыйтов, чыгып барышлый үчлекле тавыш белән.— Ясалма рәвештә минем эшне тоткарламакчы буласың. Сәбәп эзлисең. Барып чыкмас! Өстеңнән таптап узам мин синең. Контр сазлыгына тәгәрәгән Муса Җәлилов ишеләрне яклап маташасың. Өлкә комитетына барам, моннан соң һәр мәкаләмне өлкә комитеты раславы белән тапшырачакмын, каршы килеп кара!

Сәгыйтов сүзендә торды, өлкә комитетында да аңа каршы төшәргә җөрьәт итүче табылмаган, ахры. Махсус резолюция салдыртып китергәч, мәкалә икенче көнне үк дөнья күрде. Шуның аркасында Муса белән Әхмәтсафаның арасы шактый суынды, аны җылытырга кабат форсат булмады инде... Язмыш аларны бер-берсеннән коточкыч тизлек белән ерагайта, моны алар үзләре генә сизмиләр иде әле...

## VI

...Яңа вазифасына баш-аяк чумып бетмәсә дә, Сәгыйтов ишеләр белән шактый тарткалашырга өйрәнеп килгән вакытта Әхмәтсафа Дәүләтъяров тормышында яңа борылыш хасил булды.

«Кызыл Татарстан» газетасы 1937 елның унсигезенче сентябрендә Татарстан АССР унынчы чакырылыш Үзәк Башкарма Комитетының җиденче сессиясе карары белән Әхмәтсафа Мостафа улы Дәүләтъяровның Татарстан Республикасы халык комиссарлары советының рәисе итеп билгеләнүен хәбәр итте.

Мөхәммәтҗанов бөртекләп үз тирәсенә туплаган яшь көчләрне мәйданга чыгарыр вакыт җитте. Кайберәүләр: «Мөхәммәтҗановка көн килде»,— дип тә уйладылар бугай. Аның тирәсендә бөтерелүчеләрнең кисәк күбәеп китүе моны ачык дәлилли иде булса кирәк.

Моңа кадәр халык комиссарлары советын җитәкләгән Кыям Абрамов белән Татарстан Үзәк Башкарма Комитеты

рәисе Гомәр Байчурин инде «халык дошманы» буларак кулга алынып, «Черек күл»гә озатылганнар иде.

Әхмәтсафаның эш буенча Кыям Абрамов белән очрашкалаганы булды. Донбасс шахталарында күмер чапкан кеше ул, ташкүмер астында калып сул кулын өздергән чулак Абрамовның яраткан җыры да шул шахтада үткән бәхетсез яшүсмер чакларын искә төшерә торган, күзләрдән яшь китергән «Шахта» җыры иде.

Әле җәй урталарында гына, Лепа тәкъдиме белән бөтен өлкә комитеты берлектә Идел буена ял итәргә чыккан иделәр. Галим Мөхәммәтҗанов Лепа белән бер төркемдә утыра, нидер сөйләп көлдереп тә ала бугай, аңа рәхәт, ә менә Әхмәтсафа бу кадәр җитәкчеләр арасында үзен уңайсыз хис итә, шуңа күрә бер кырыйдарак йөрүне хуп күрде. Кисәк каршысына Кыям Абрамов килеп чыкты. Нигәдер Чулак Абрамнан шүрли иде Әхмәтсафа. Буй-сынлы, чәче дулкынланып тора, чибәр бу кеше яшьли фирка эшендә чарланып, үз сүзен турыга ярып әйтә, һәрвакыт нидер исәпләп йөргән кебек. Шуңадырмы, кырыс күренә. Үзара гәпләшкәндә, Мөхәммәтҗанов аны яшьләргә ышанып җитми, дип, еш кына тиргәп тә ала иде. Әхмәтсафага да ул өстәнрәк караган төсле тоелган иде. Кыям Абрамов аптырабрак калган Әхмәтсафаның иңсәсенә дусларча кагып алды:

— Ник аптырап йөрисең, канәт?..

Дустанә эндәшүгә ни дип җавап бирергә белми Әхмәтсафа авыз эченнән ботка пешереп алды:

— Район тормышыннан соң, шәһәргә ияләнеп җитеп булмый бугай...

— Бәй, кит тә бар, кире районга, анда булдыклы егетләргә кытлык...— Абрамов шаркылдап көлде.— Юк инде, канәт, җибәрмибез сине кире авылга. Безгә кирәк күренәсең... Әйдә, Идел буена барып килик әле...— Җавап көтмәстән, биек ярга табан атлады. Ирексездән Әхмәтсафа да аңа иярде.

Кыям Абрамов, янында басып торган егеткә игътибар итмәстән, Идел киңлекләренә карап, моңсу тавыш белән суздык:

Шахталарга мин төшәмен,  
Җырлап күмер кисәмен.  
Гомрем булып, таш басмаса,  
Ташламам җан кисәгем...

Идел өстеннән искән дымсу, салкынча җил тәнгә рәхәтлек бирә иде. Абрамов күзен кыса төшеп, көмештәй ялтырап аккан су өстенә карап торды да яр читенә үк килеп утырды.

— Адә, канәт, утыр. Шышы ямьне ничек ташлап китәсе, ә?

Әхмәтсафа ни дип җавап бирергә белмәде. Сорау аңлашылмый иде. Ни өчен китәсе, кайда китәсе, кайчан?..

— Думави дөрес әйткән, Дәүләтъяров, «хөрмәтле яшь

гомерем» дип язган бит ул, әйеме... Андый шагыйрьне ишеткәнең бармы? – Җавап көтеп тормый, сүзен дәвам итте.— Уйлап баксаң, никадәр тирән әйткән бит: сөенече дә, үкенече дә шул сүзләргә сыйган. Шыңа шагыйрь халкын особый диләр дә инде. Хөрмәтле яшь гомеркәйләр үтте-китте менә. Сезгә кала дөнья, бездән сезгә... Бик гади дә кебек югыйсә, килү бар, китү бар. Барыбыз да бертөрле киләбез дөньяга, китүләр генә төрлечә... Мөхәммәтҗанов ашыга, каударлана ул. Шуңа Байчурин белән мине өнәп тә бетерми. Яндырасы килми егетне, утка кергәнен сизми, бөтен бәла шунда. Без яшь, белемле, милли кадрларга каршы түгел, үссеннәр алар, ишәйсеннәр, көч тупласыннар, бер-берсенең кадерен, кирәген белсеннәр, төзесеннәр без төзеп җиткермәгән ирекле Татарстанны, дип аңлатмак булабыз, шул позицияне егеткә сеңдерергә тырышабыз. Ә ул...— Абрамов, ачынып, сыңар кулын читкә селтәп алды.— Их, чурту, янмаска иде дә...

Көчле, кыю, туры кешенең кинәт «халык дошманы» булуына ничек ышанырга?.. Буа районы Иске Тинчәле авылы егете, Альфред Лепадан бер генә яшькә кече, әле җиң сызганып эшләп йөргән көннәре иде. Июльнең соңгы көнендә кулга алганнар дигән хәбәре иреште: газетта кереп китәсе бөтен мәкаләләрдән Абрамов фамилиясен алып ташларга боерык килеп төште.

Гомәр Байчурин исә Саба ягыннан, Мишә елгасы буенда үскән ир-егет. Лепа белән Абрамовка караганда күпкә өлкән, тормышны яхшы белә, шуңа аның белән исәпләшәләр, киңәштабыш итеп эш йөртәләр иде. Базык, әмма нык гәүдәле, кара чәчле, куе мыеклы. Күп сөйләшергә яратмый иде. Ул да Кыям Абрамов кебек яшьли шахталарга төшеп күмер чапкан, патша армиясендә хезмәт итә, гражданнар сугышында катнаша, Арча районында Татарстанда беренчеләрдән булган «Колай» совхозын оештыра. Егерменче еллар уртасында ул Минзәлә кантонында эшли, шуңа күрәдерме, очрашкан чакларда, Әхмәтсафага: «Саумы, якташ!» — дип, күрешергә кул суза иде. Ул сак астында икән, аның фамилиясен дә Әхмәтсафа үзе карап торып газет битләреннән алып ташлаттырды...

Лепаны бераз соңрак, сентябрь аенда Мәскәүдә кулга алып, Казанга озаттылар.

Галим Мөхәммәтҗанов бу этапта үзенең Беренче була алмавын да чамалап алгач, үзен кая куярга белми йөрде. Курыкканы — аның да Лепа артыннан «Черек күл»гә озатылу мөмкинлеге. Алемасовны Беренче итеп сайлап куйгач, берара югалып калган булса да, бу халәттән айныгандай булды. Вакыйгаларның барышы аңа бөтенләй үк кире дә түгел сыман. Маленков та, Алемасов та миңа ышаналар, мине саклап калырга

тырышалар, ахры, дигән уйдан бераз тынычлана төште һәм һәр адымында шушы ышанычны акларга әзер икәнен күрсәтергә омтылып, эшкә ябышты. Болай уйларга сәбәп тә бар — Алемасовка республиканың дилбегәсен тоттырган көнне үк, Маленков үз янына нәкъ менә Мөхәммәтҗановны чакырды.

Галим каушап, ни уйларга да белми кергән иде Мәскәү вәкиле янына, аннан кош тоткандай чыкты.

Маленков, Сталинга охшарга тырышып, Мөхәммәтҗановның барлыгын да искәрмәгән кыяфәттә, ишекле-түрле йөрештереп алгач, сынаулы караш ташлап, Мөхәммәтҗановка карап катып калды. Аннан арган төс белән сорау бирде. Әйтерсең бу сорау аның җанында өч атна йөреп, үтенә тигән дә хәзер генә якты дөньяга чыгарырга форсат туган:

— Татреспубликада абруйлы, белемле, яшь, шул ук вакытта халык комиссарлары рәисе йөген дә тарта алырлык тәҗрибәле милли кадр бармы?..

Галимнең башына шаулап кан йөгергән кебек булды. Нәрсә диярга? Әгәр үзенең кандидатурасын күрсәтсә? Бәлки, Маленков аннан шундый җавап көтә торгандыр. Алай дисәң, кайчан гына өлкә комитетының икенче секретаре итеп сайланды ул, җаваплылыктан кача кебек булып чыкмасмы? Көттереп кенә Галим үз сүзен әйтте:

— Бар андый кеше, иптәш Маленков. Дәүләтъяров фамилияле бик төпле егет бар,— дип җавап бирде.

— Аңа Алемасовның карашы ничек?

Галим сәяси уеннарда шактый чарланып килә иде, хәйләгә күчте.

— Иптәш Алемасов вакытында сәяси аренага чыкты ул. Моңарчы аңа юл бирмәделәр...

— Шәхси делосын туплап бирегез, мин аны Мәскәүгә алып китәм,— диде Маленков.— Тагын берничә кандидатура уйлап куегыз. Монысы үтмәве дә мөмкин.

...Болай да борчулы көннәр үткәргән Галим Мөхәммәтҗановның башына янә бер кайгы төште: Дәүләтъяров белән янмасмы, черт возьми. Бәхетенә, Мәскәүдән өстәмә кандидатура сораучы булмады. Әмма тынычланып та булмый, иң нык үткә тигәне — Дәүләтъяров хакында Югары Совет сессиясе булачак көн җиткәнче Алемасов ләм-мим бер сүз әйтми йөрде. Сессия көнне иртән генә, кисәк Мөхәммәтҗановны үз янына чакырып:

— Рәислеккә без тәкъдим иткән кандидатураны Үзәк Комитет хуплый, Дәүләтъяров белән сөйләшеп алсаң да була...— диде.

«Без» дигән сүзне ишеткәч, Мөхәммәтҗановның эченә җан керде. Димәк, Алемасов белән аның борчагы пешәчәк! Кайбер катлаулы мәсьәләләрне хәл иткәндә Алемасовка

ышыкланырлык, «без» исеменнән сөйләрлек берәү кирәк булуы аңлашылмаслык нәрсә түгел, бигрәк тә бүгенге вазгыятьтә. Куркып, шикләнеп йөрүдән туктарга вакыт! Үзеңнең республикада реаль властька ия икәнлегеңне белдерер көннәр җитте дип куанды ул. Бу минутта ул үзен капкыннан ычкынган затлы киек итеп хис итте.

Халык комиссарлары рәисе итеп Әхмәтсафа Дәүләтъяровны бертавыштан раслады лар.

Бу хәлләргә, исән булса, Гомәр агасы, ягъни агабзыкай ничегрәк бәя бирер иде икән? Әле Урта Азиягә китеп, җаваплы вазифаларга билгеләнгәч тә, аның әйткән сүзләре исеннән китми. «Биек мендең, үз сукмагың белән мендеңме, әллә эткәләп-төрткәләп торучылар булдымы? — дигән иде ул аңа, акыл биргән тавыш белән. — Үз сукмагың белән менсәң, ярый торган эш ул күтәрелү. Этеш-төртешкә калса, андый нәрсә алдаучан була. Тиз түбән очарга мөмкин адәм баласы, андыйлар, күп очракта, аякларына яңадан баса да алмыйлар инде, имгәнеп, зәгыйфьләнеп калалар». Соңгы очрашуда, инде үләр алдыннан моңсуланып ул Әхмәтсафага сәер сүзләр әйткән иде. «Адәм баласы тешен кыса-кыса дөньядан китмәс өчен тырыша-тырмаша. Минем менә яшәргә җан тырмашып ятасым килми. Китәргә, тизрәк дөнья белән алыш-бирешне өзеп, Ходай хозурына җитәсем килә. — Аптырап калган Әхмәтсафага кызганган шикеллерәк карап торды да сүзләренә ачыклык кертте. — Ике нәрсә үлememне үкенечле итми: беренчесе — карчыгымнан ятим калгач, миңа яшәүнең тәме, мәгънәсе, яме китте; икенчедән — минем сез төзегән денсез тормышта бер генә көн дә торасым килми. Аллаһ дисәң, җанга рәхәт, аны куйсаң, тәнгә рәхәт... Борынгылар сүзе. Тән рәхәте белән генә булмый шул, җан рәхәтеннән аермасын Ходай. Сез тән рәхәтенә баш куйдыгыз. Афәтнең төбе шул. Мин әүвәлге хозурлыклар, иманлы дәверләр хакында уйланып көннәр, төннәр үткәрәм, шул арада гомерем шәменең мае кимүенә сөенеп ятам». Агабзыкайның истә калган соңгы сүзләре шул булды.

Утызынчы елда аның үлү хәбәре килде. Тормышның мәгънәсен үзенчә аңлатып, төшендерүче изге затның китүен Әхмәтсафа эш-мәшәкатьләр белән артык хафасыз гына үткәреп җибәргән сыман тоелса да, Гомәр ага һич көтмәгәндә искә төшеп, йөрәкне нидер яндырып үткәндәй була. Өлкәннәрнең акыллы сүзләренә, киңәшләренә адәм баласы һәрчак мохтаҗ икән шул, алар исән булганда гына кадерләрен белеп бетермибез, китеп баргач, күпме генә үкенмә, алар инде кайтмыйлар. Хәтердә терелеп, истәлекләрдә генә яши Гомәр агай. Яңа тормыш дигәнне аңламады ул. «Бә-әк катлаулы

итеп төзисез яңа тормыш дигәнегезне... Тормышны катлаулы-катмарлы итеп бетерү өчен акыл күп кирәкми аңа. Яшәүдән хозурлык таба алырлык булсын ул, гади, аңлаешлы итеп төзеп карагыз сез аны. Кеше ирекген чикләми төзегез. Вәт булырсыз блач! Мөселман мөселманча яшәүдә ирекле булсын, носарилар үзләренчә ирекле булсыннар, бер-берсенә теш кайрамый яшәсеннәр, тормыш корсыннар. Сез ничек төзисез соң? Кешеләрне бер-берсеннән читләштерәсез, аерымлыйсыз, сәбәпсез дошманга чыгарасыз. Ходайдан узып, кешеләр язмышына хуҗа булмакчысыз. Илне кулга алырга була ул. Халыкны көтү мисалына калдырып булмый. Кайчан да булса тарала ул халык дигән көтү. Язмыш дигәнең бит меңгә төрләнә, үзгәрмәс бер генә нәрсә бар, ул — кеше күңеленә ана сөте белән кергән иман. Дәрдмәнд әйткәнчә: «Сөт калыр, Ватан китәр! Сөт калыр, Ватан китәр!» Алтын тавы өстендә утырган Рәми хәзрәтләрен ачтан үтерде яңа блач, мин яшәп азапланам әлегә. Ни кызыгы, ни яме мондый яшәүнең? Сәер кешеләр сез, сәер тормыш корасыз...»

Ул вакытта Гомәр агайның әлеге сүзләрен һич тә тыңлап торасы килмәгән иде, баксаң, дөрескә чыгып бара бит картлачның сүзләре. Инде аны туктаусыз өскә күтәрәләр, җаваплы вазифалар йөклиләр, ә менә шушы хәлгә күңелдә аз гына да сөенү хисе юк. Сәер түгелмени?!

Гомәр агай вафатыннан соң, аны үткәннәр белән бәйләп торган соңгы җеп тә өзелгән шикелле булды. Кая барса, ни эшләсә аны кемдер күзәтәдер, гамәлләренә бәя бирәдер дигән тойгы юкка чыкты, ул инде беркем алдында да җавап тотмый, мондый җавапның кемгә дә булса кирәге дә юк, барысы да үз иркендә, барысы да үз җае белән барырга хаклы иде кебек.

Үзен халык комиссарлары советы рәисе итеп сайлап куйгач, саран (элекке кебек һәр уңышны рәхәтләнеп билгеләп, бәйрәм итүләр бетеп бара иде инде. Беркем дә иртәгесен үзе белән ниндиерәк хәлләр буласын белми. Ил буенча тоташ кулга алулар бара...) котлаулардан соң, комиссарлар советы рәисе бүлмәсенә кереп, күн кәнәфигә килеп утыргач, башында уй туе бөтерелә башлады. Эчен нәрсәдер яндырып алгандай булды, урыныннан сикереп торып, тәрәзә янына килде. Казансу ярында буш көймәләр чайкала. Хуҗалары бермәл эчендә каекларын калдырып, үзләре каядыр китеп барган сыман. Инде хәтер буйлап Мифтах хәлфәнең шәүләсе йөгереп үтте. Хәер, шәүләсе дә түгел, сүзләре бәгырен яндырып алды: «Һай, син татар, һай, татар, син бит кичә бар булдың, син бит бүген юк булдың!.. Заман синең заманмы, Дәүләтъяр оныгы? Дәвер синең дәверме, Дәүләтъяр оныгы?.. Азамат ир торышың, ничек илкөн кормышың?.. Ихтыяр тезгенең учыңа уралганмы, әллә ул

башкалар кулындамы? Ни кормак буласың да, ни кырмак буласың, балакай?.. Ил-йортыгыз үчлектән җимерелгән, яңа нигезегез ялганнан корылган». Мифтах хәлфә менә шулай уйнатып, чалулатып, фикер җебен чуалтыбрак сөйли иде. Бу сүзләр Әхмәтсафаның бүгенге халәтенә бәйләнешле дә кебек, юк та кебек, әмма җан урыныннан купты, тынгысызлык йөрәкне талкый, ул, дөньядагы һәрнәрсәгә ышанычы югалган хәлдә бөкрәя төшеп, кабат зур өстәл артындагы күн кәнәфигә кереп чумды. Үз уйларына күмелеп, оеп утырырга шәп икән ул кәнәфи дигәннәре. Кисәк урыныннан купкан күңеле бераз тынычланды. «Тезген безнең учта булыр, башкача булыр шикелле түгел ул!» Ул эченнән генә Мифтах хәлфә белән бәхәскә кереп алды. Мин монда икәнмен, димәк, Дәүләтъярныкы дәвер. Абынмаска, егылмаска гына иде беренче айларда ук. Әлегә буыннар сыек, әмма ныгыр алар, көч тә, куәт тә арта төшәр, азамат ир яшендә генә ич әле ул. Барысы да алда әле! Монда утырган һәркем Кыям Абрамов язмышын кабатламас бит инде. Димәк, Кыям абзый үзе дә гаепле шундый хәлгә төшүенә, димәк, алдын-артын карап бетермәгән... Кешеләргә артык ышанып, кирәкмәгән сүзләр дә ычкындыргандыр әле. Кешеләр янында булырга, алар белән гәп сатарга һәвәс иде ул. Бер дә, бер дә гөнаһсыз алып китеп япмый торганнардыр инде «Черек күл»гә? Сәбәп булмаса, һәркемнән, һәрнәрсәдән кем генә дошманлык эзләп йөрер икән...

...Озак та үтми яңа вазифаның «җимешләрен» дә татый башладылар.

Иң элек халык комиссарлары рәисенә тәгаенләнгән яңа фатирга күченделәр. Эшләр идарәсеннән махсус җибәрелгән йөкчеләр, элекке фатирдагы әйбер-караны эһ дигәнче машинага төяп, Гоголь урамындагы егерме бишенче йорт, беренче фатирга китереп бушаттылар. Шәһәрнең нәкъ уртасында, аулак урында, иркен фатирга күчеп килгәч, бүлмәдән бүлмәгә йөргән Хәлимә әбинең куанычы эченә сыймады.

— Шушы йортта бәхетле гомер уздырырга язсын, оланнар,— дип, теләк тели-тели һәр бүлмәгә кереп дога кылып чыкты.

Әнисенең сөенечтән нишләргә белми, туктаусыз дога укып йөрүен килештереп бетермичәме, Рабига Әхмәтсафаны ишегалдына өстерәде:

— Әйдәле, бернәрсә күрсәтәм,— диде ул, аяк арасында уралган Маратын читкә этәрә төшеп. Марат исә агач кылычын әтисе бүләк итеп алган әкият китабындагы юлбасар кыяфәтендә болгап, кычкырып җырлап җибәрде:

Бог создал вора,
А черт прокурора. Эх...

Рабига Маратның колагын нык кына борып алды. Йөзе кызарып чыкты. Кеше ишетсә... Урамда ни күрсәләр, ни

ишетсәләр, хәзер күңелләренә сеңдереп тә өлгерәләр бит болар. Маратны инде әйтәсе дә түгел. Хәерсезләр, бу малайларны тәрбияләүне әнисе — Хәлимә абыстайга гына тапшырып, ерак китеп булмас. Яхшырак балалар бакчасына урнаштыру җаен карарга кирәк...

Әхмәтсафаның башы әйләнгән чак, Маратның шуклыгына артык әһәмият биреп тормады, хатынына берсүзсез буйсынып, ишегалдына чыкты.

— Нәрсә, җанаш? — диде ул, Рабиганың беләгеннән эләктереп.— Әллә тегендә чакырасыңмы? — дип, мут елмаеп, ишегалды түрендәге таш сарайлар ягына ым какты.— Канның уйнаган чагы, карчык, кыздырма болай...

— Ну сине!..— дип, Рабига ирен читкәрәк төртеп җибәрде.— Юк-бар турында гына уйлыйсың. Ишеттеңме, Марат нинди урам җырлары өйрәнеп кайткан? Марлесы аңа ияр. Ике хулиган үстереп ятабыз. Эш-эш дигән булып, балаларны әни өстенә ташладык та, вәссәлам. Беренче сүзем шул иде. Аларны яхшырак бакчага урнаштырасы иде. Синең мөмкинлек белән...

— Бәй, сиңа әйтмәдеммени әле? — дигән булып, Әхмәтсафа сыңар кулы белән Рабиганың биленнән эләктереп алды.— Бу мәсьәлә хәл ителгән инде, менә сиңа ике юллама, Марат белән Марлесны иртәгә үк шушы адреста күрсәтелгән бакчага йөртә башлыйсың.— Икенче кулының ике бармагын җәһәт кенә күлмәгенең түш кесәсенә шудырды һәм аннан алсу кәгазь тартып чыгарды.

Рабига, юлламадагы бакча санын күргәч, кулларын чәбәкләп алды.

— О-о, элитный бакча бит бу, Сафа җаным. Безнең балаларны кертерләрме?

Әхмәтсафа сүз куертмады, борчылма дигәндәй, Рабиганы үзенә кыса гына төште. Инде шаяртудан туктап сорасы итте:

— Икенче серең нәрсә иде, анысын да яшермә инде, шулкадәр каударланып ишегалдына өстерәдең, башка мең төрле шик керде.

— Тышкы яктан тәрәзәләрне сана әле. Ничәү? — Чыннан да Рабиганың тавышында серлелек бар иде.

Әхмәтсафа сәерсәнеп китте. Йортны ашыгып әйләнә-әйләнә тәрәзәләрне санап чыкты.

— Сигезәү, карчыгым. Ә нигә кирәк булды бу?

— Шуңа,— диде Рабига, пышылдап диярлек.— Эчке яктан санадым, җиде генә тәрәзә чыга. Күзләремә ышанмыйча, өч мәртәбә санап чыктым. Менә бу уртадагы челтәр корганы тыштан гына шулай тәрәзә кебек, баксаң, ялган ул, эчке яктан такта белән кадаклап, сылап-буяп куелган. Ялган тәрәзәле йортка китереп керттеләр безне. Хәерлегә булсын...

— Йә, Рәбуш, юк-бар сөйләмә әле. Хорафатлар чоры үт-

те. Тү-тү инде алар. Бу йорт хан заманында салынган. Кемнәр ничек кенә үзгәртеп бетермәгәннәрдер. Әйдә, әнә Марлес еларга азаплана, керик.

— Марат үрти инде аны. Һич тиктормас булды шул малай. Үзеңә охшаган... — дип, Рабига өйгә йөгереп кереп китте.

Әхмәтсафа папирос кабызып, ап-ак челтәр корылган ялган тәрәзәгә озаклап һәм сәерсенеп-гаҗәпләнеп карап торды.

## VII

Һәр яңа эшкә Әхмәтсафа алны-ялны белми ябыша. Эшеннән мәгънә табып, булсын дип йөргәч, нәтиҗәсе дә көттерми, кешеләр арасында абруе арта, аның тирәсенә булдыклы егетләр җыела, шау-гөр килеп серләшәләр, кайчак, чаманы онытып, бәхәскә дә кереп китәләр һәм еш кына бу бәхәсләрдә Дәүләтъяровның дәлилләре көчлерәк, ышандырырлык була, аның белән килешергә туры килә. Бәхәс артыкка китеп, тәртип кысалары бүселеп, әңгәмә күңелсез рәвеш ала башласа, Әхмәтсафаның салмак, ләкин көчле тавышы ишетелә:

— Дөрес, әмма алай түгел ул! — ди ул, Мифтах хәлфә кебек уң кулының имән бармагын өскә чөеп.— Китап менә болай ди! — Елмая төшеп, әле генә очы-кырые күренмәгән бәхәскә китереп терәгән мәсьәләнең чишелү юлларын санап күрсәтә башлый. Зирәк акыл, тимер мантыйк, тәҗрибә һәм белем өскә чыга, бәхәскә нокта куела.

Ул, халык комиссарлары советына килү белән, җентекләп Татарстанда хуҗалык үсеше перспективаларын өйрәнде. Билгеле, монда аңа яңа нәрсә юк. Минзәләдә, Кызыл Йолдыз районында эшләгәндә, Татгосиздат яки «Кызыл Татарстан» белән җитәкчелек иткәндә дә, айга берничә мәртәбә өлкә күләмендәге җыелыш-киңәшмәләрдә катнаша торды, берсенә берсе охшаш чыгышларны тыңлап туеп беткән иде, әмма үзе төп эшкә — ХКС рәисе вазифасына алынып, һәммәсен яңадан күздән кичерә башлагач, көтмәгәндә «өченче күз»е ачылды — бәй, алга барабыз дип сөйләнгән булабыз чынлыкта бер урында таптанып гомер үтә икән ич! Хуҗалыкны дәвергә яраклаштырып, ныклы платформага куям дисәң, акыл казаны — һәр яңа идеяне үстерерлек, көч-куәт бирерлек үзәк юк икән бит Татарстанда. Сәнәгатьнең төп моторы — электр энергиясе, әмма зур-зур җитәкчеләр дә электрны фатирларда чекерәеп янган лампа диеп аңлаудан ерак китмиләр. Ярым-йорты белемгә ия надан түрәләргә энергетика куәтләрен үстерми торып, алга китеш булмаячагын ничекләр генә аңлатырга? Үзен алланың кашка тәкәсә санаучы надан түрә башкаларны ничек эшкә дәртләндерсен?.. Эшне төптән җигелеп тарта башлагач кына, Мөхәммәтҗановның туктаусыз:

«Кадрлар, кадрлар кирәк!» — дип өзгәләнүен аңлады. Яңаларны үстерү авыр эш, булганын да саклап калу кыен.

Әхмәтсафаның иң үзәгенә үткәне — туктаусыз кулга алулар. Инде бер тармакка булдыклы, белеме, тәҗрибәсе булган кешене табып куясың. Ике-өч атнадан ул «юкка» чыга, баксаң, «халык дошманы» икән, кулга алынып, «Черек күл»гә озатылган, имеш. Белгечләрнең җитмәве һәр адымда сиздерә. Күр инде син, Казанда гөрләп барган ТЭЦ төзелешен Алемасов ни өчендер әһәмиятсез дип табып, туктатырга әмер хәзерләргә кушкан икән.

Октябрь урталарында Дәүләтъяров бу төзелеш хакында материаллар туплап, Алемасов янына керде.

Беренче Әхмәтсафаны битараф кыяфәттә тыңлый башлады. Ничек инде ул кабул иткән карарны кире кагарга мөмкин? Ник кирәк ул икенче ТЭЦ Казанга? Кемгә хаҗәт ул? Берәү бар, шул бик җиткән. Татарлар көне-төне электр яктысы астында яшәргә маташамы? Ул бер селтәнүдә сүзне өзеп, яңа рәисне кабинеттан куып чыгарырга ниятләп кәнәфиеннән күтәрелә төшкән иде, ниндидер көч кире урынына кадаклап куйды.

Дәүләтъяров һәр җөмләсен мисаллар белән ныгытып, шундый дәлилләр китереп сөйли бирде, аны туктату өчен ахмакның да ахмагы булу кирәк иде. Ә Алемасов ахмак түгел, җилнең кай тарафка искәнен тиз төшенде. ТЭЦ төзелешен аның боерыгы белән туктату, гомумән, төзелешне икенче планга калдыру — үлемгә бәрабәр икән, ләбаса. Тиз арада ТЭЦ төзелеп, электр куәте бирә башламый икән, Казан төпсез чуманга утырып калачак, дип раслый Дәүләтъяров. Калган башка төзелешләр дә графиктан чыгып, Татарстан адәм көлкесенә калачак. Куркыныч сүзләр бит бу, шайтан алгыры! Мәсьәләнең җебен дөрес эләктергән татар малае, әгәр тиз арада Мәскәү күзенә хуҗалык үсешендәге үзгәреш, алгарышлар белән чалынып алмасаң, сиңа кул селтәргә дә күп сорамаслар. Вакыт уза, күлмәк туза. Барысын да «халык дошманнары»на аударып кына да котыла алмассың. Алемасов яхшы белә, хәлләр шундый тизлектә куера ки, көннәрдән бер көнне үзеңнән дә дошман элементы ясарга күп сорамаслар. Энергетика куәтләрен сафка кертмичә, республикада сәнәгатьне алга җибәреп булмаячак. Авыл хуҗалыгына ышаныч юк, яңгыр вакытында яуса — иген уңа, корылык килсә — ачлык. Икмәк Ходай кулында. ТЭЦ төзелешен кичекмәстән беренче чираттагы эшләр исемлегенә кертергә, бу хакта шаулый башларга, эш күрсәтү инициативасының Беренче кулында булуын һәрчак искәртеп торырга кирәк. Ничек кенә булмасын, Татреспубликадан бер орден да эләктереп китмәсәң ни-нәрсә була ди? Әнә үзәк газитләр Мәскәүдә «халык дошманнары»н кыйраткан проку-

рорларны орденнар белән бүләкләү турында саннан санга язып торалар, ул, Алемасов, Казанга килеп күпме корткычның башына җитте, эше күренсен дип, әле сентябрь башында гына бер төркем милләтчеләргә, татарны күккә чөйгән ялган тарихчыларга беренче категория бирдерүгә иреште. Аларны көнендә үк чыгарып аттылар. Бу хакта Ежовның турыдан-туры үзенә хәбәр юллап тора, әмма «тимер нарком» һаман дәшми. Шулай да сентябрь башында булган бер сөйләшүдә Татреспубликада өч-дүрт мең контрны җыеп алырга разнарядка бирергә җыенуын белдергән иде Ежов, зуррак «асыл кошлар»ны эләктереп булмасмы дип тә сорады. Мәдрәсә шәкертләре тәмам туйдырды, андый эшләрнең кызыгы да үтеп бара дип, шелтә дә белдергәндәй итте.

Алемасов комиссар Усманов «эше» белән ныклап кызыксына башлавын әйтеп куйды. Бу инде ничарадан бичара, үзенең дә кайбер телгә алырлык эшләре булуын искәртү өчен сөйләнеп азаплануы иде. Усманов Мәскәү өчен никадәр кирәктер, ләкин Казанда аның абруе искиткеч зур. Усманов турында сүз чыккач, Ежов кайнарланып, Алемасовның кулын кысып алды.

— Ниһаять, ниһаять... — Ежов мәкерле елмайды. — Еланның иң агулысы синең кулда икән. Солтангалиевтән соң икенче дәрәҗәдәге дошман ул, Александр Михайлович. Бу бәндәне чиста суга чыгарырга күптән вакыт. Белеп тор, Усманов — игелексез нәрсә, «Татреспубликада радионы беренче булып мин оештырдым», — дип мактанып йөри икән. Халыкны ышандырып бетергән шушы ялганга. Бу хакта материал килеп кергәнгә байтактан, инде Усмановның яз көне үк кулга алынуы турында хәбәр иттеләр, ә результат күренми.

— Җитешеп булмый, иптәш Ежов. Бер милләтче-контрреволюционерның телен ачу өчен генә күпме көч сарыф ителә. Татарлар кадәр кире, үҗәт халык...

— Халык түгел,erткычлар! Мин сине аңлыйм, әмма ялганга чик куярга кирәк. Беләсең килсә, иптәш Алемасов, әле мең тугыз йөз егерме беренче елда ук мин Казанда беренче радио түгәрәкләре оештырган кеше. Моны исәпкә алмый, радио оештыру эшен Усманов исеме белән бәйләү, ахмаклык кына түгел, иң зур сәяси хата, күренекле Совет җитәкчеләренең хезмәтләрен таптау! — Ежов түшен киереп куйды. — Усманов — милли армия төзим дип, Троцкий алдында шуышып йөргән кеше, сөяген сөяккә аерыгыз, әмма кирәкле фактларны каерып алыгыз үзеннән. Аның һәр күзәнәге шпионлык информациясе белән тулышып, шартлар дәрәҗәгә җиткәндер инде. Сез, беркатлыланып, теле ачылуын көтеп, аны төрмә ипие белән симертеп ятасыз. Вак-төяк шакаллар белән вакыт сарыф итәсез, ата дошманнарга кулыгыз җитми!

Солтангалиевне дә Татарстан карамагына бирәбез, Галимҗан Ибраһимов... Менә эш фронты сезгә! Һәркайсы йөз милләтчегә торырлык эшләр болар... Кирәклесен сыгып чыгара алсагыз, тырышлык тиешенчә бәяләнер. Әлегә эш күренми, мактыйсы бик килә, әмма... әмма... Минем тарафтан сиңа йөз процент ышаныч, алга, иптәш Алемасов!

Дәүләтъяровның ТЭЦ төзелеше турындагы сүзләреннән соң бертын калып, шулар хакында уйланды, аннан кинәт күтәрелеп, бу тынлыктан соң ни буласын, ни ишетәсен белмичә тилмереп утырган рәискә күз ташлады да нindидер саңгырау тавыш белән сорау бирде:

— Усманов хакында беләсеңме, Дәүләтъяров?

— Шамил Усмановнымы?

— Димәк, беләсең...

Комиссар Усмановның кулга алынуы хакында хәбәрдар иде. Мондый очракта нәрсә диярга?.. Сорауның юктан гына бирелмәвен яхшы аңлый Әхмәтсафа.

— Беләм дип әйтү өчен, кеше белән бер пот тоз ашарга кирәк, иптәш Алемасов. Гражданнар сугышы чорында, аннан соң бер-ике мәртәбә очрашырга туры килде аның белән.

Алемасов, җавапны тыңлап тормастан, Усманов хакында ничек көтмәгәндә сүз кузгатса, шулай ук тиз туктатты да.

— ТЭЦ дисең инде син. Төзелешне җанландыру өчен нәрсә эшләргә кирәк беренче чиратта?

— Кадрлар юк, иптәш Алемасов. Шунсыз зур төзелешне хутка җибәреп булмаячак.

— Кадрлар кая соң алар? Булганнары кая киткән, дим.Тиктомалдан төзелеш корып җибәрмәгәннәрдер бит?

— Булдыклы кадрлар... кулга алынган...

— «Халык дошманнары»н булдыклы кадрлар дип атарга ничек телең әйләнә, Дәүләтъяров? Үз акылыңдамы син? — Алемасов кызып китте, чөнки ТЭЦтагы күп инженерларны нәкъ менә ул килгәч кулга алганнар иде.— НКВД бер генә кешене дә гаепсезгә кулга алганы юк. Кулга алынган икән, димәк, гаепле! Беләсең килсә, аларның һәркайсы үз гаепләрен танudылар инде, авырлык белән, таш-тимер каршылыклары күрсәтәләр, әмма таныйлар. Шуның өчен дә дошманнар дип атала алар... Гаепне тану — исбатлауның патшасы!

Дәүләтъяров чыгып киткәч, Алемасов янә уйга калды. Кемнәр бөтерелә аның тирәсендә, беренче ударны кемнәрдән көтәргә? Өлкә комитетында, халык комиссарлары советында, ТатЦИКта вазифа башкаручыларның һәркайсын кат-кат күздән кичерде. Әмма ике кеше генә әлегә саруын кайната иде — берсе, икенче секретарь, әле ике-өч ай гына Беренче урынына дәгъва кылып йөргән Галим Мөхәммәтҗанов, икенчесе — нык ихтыярлы, белемле, күзгә туры карап сөйләшүче

халык комиссарлары советы рәисе Дәүләтъяров. «Егетне ныклап өйрәнергә кирәк! Мөхәммәтҗанов белән Дәүләтъяров аның кешеләре түгел. Ул аларны белми, үзе үстергән кадр дип тә әйтә алмый. Болар, яшь булсалар да, теге буыннан калган мирас, аларның микроблары белән туенып өлгергәннәр. Җай чыккан саен аларның җырын җырлаячаклар...»

Алемасов телефонга үрелгән иде, секретарь кабул итү бүлмәсендә Мөхәммәтҗановның көтеп торуы хакында хәбәр итте.

— Керсен,— диде Беренче секретарь, нигәдер сөенгән шикелле.

Мөхәммәтҗанов кабинет буйлап йөгереп кенә үткән шикелле тоелды. Аның йөзендә ризасызлык билгеләре ярылып яткан кебек. Алемасов керүчегә астан гына күз төшереп алды да ниндидер кәгазь кисәген укып-өйрәнгән булып утыра бирде.

Икенче секретарь, сүз башларга җыенып, тамак кырды.

— Ни бар, Мөхәммәтҗанов?

— Нәрсә дип әйтим, иптәш Алемасов?.. Дәүләтъяров белән киңәштем дә...

— Кайчан өлгердең? Дәүләтъяров әле генә миндә утырып чыкты. ТЭЦ төзелеше хакында кызыклы фикерләре бар. Кстати, минем фикергә каршы килмиләр алар. Төзелешне кичекмәстән беренчел эшләр исемлегенә куярга кирәк.

— Шуңа кердем дә, иптәш Алемасов,— Мөхәммәтҗановның йөзе яктыра төште.— Хәтерегездә булса, мин дә бу хакта сүз кузгатып караган идем... Төзелешне туктату урынлы булмас, дип.

— Сүз кузгату гына җитми, иптәш Мөхәммәтҗанов, дәлилләр, масштаблы фикер кирәк! Онытма, минем ТЭЦ төзелешен туктатам дигән чагым булмады. Каян килде бу сезнең башка? Дәүләтъяров белән икәүләшеп мәгънәсез нәрсә уйлап тапкансыз. Чүбек чәйнәп, май ясаучы осталар! ТЭЦ төзелеше пүчтәк нәрсә түгел, иптәш Мөхәммәтҗанов. Куәтле энергетика базасына ирешми торып, республиканы индустриаль төбәккә әйләндереп булмаячак. – Алемасов ХКС рәисе сүзләрен кабатлап утыруын абайлап, шып туктап калды.

— Дөрес әйтәсез, иптәш Алемасов.— Мөхәммәтҗанов «нәкъ безнең шикелле үк» димәкче иде, бәхәскә кереп китүнең ни-нәрсә белән бетәсен чамалап, тынып калды.

— Ну сез, татарларны! — Алемасов, җиңел генә урыныннан торып, Мөхәммәтҗанов каршысына килде.— Эгоизм чире көчле сездә. Берегез чак кына эш күрсәтсә, хәзер аның түбәсенә дегетле чиләк каплап куярга омтылыш башлана. Дәүләтъяров ТЭЦ төзелеше турында уйлаганын әйтеп чыгып китәргә өлгермәде, инде син дә нәкъ шушы ук мәсьәлә белән минем янга килеп кергәнсең. Ничек аңларга моны?

— Дәүләтъяров белән без фикердәшләр... Аңа карата бернинди каршылыгым да юк. Сез ни өчен алай уйлагансыздыр?..

Алемасов авыз чите белән елмайды. Усал елмаю иде бу.

— Әлегә каршылык юк, диген... Алдагысын күрербез. Шулай да Дәүләтъяров өчен Байчуриннар белән «сугышып» йөрүеңне онытма син. — Әлеге сүзләрдә дә киная бар сыман тоелды. — Вазгыять тиз үзгәрә, иптәш Мөхәммәтҗанов. Кадрларны сайлап алу бер нәрсә, аларны тәрбияләү, эшчәнлекләрен анализлап тору икенче нәрсә. Миңа бер көндә Дәүләтъяровка кагылышлы өч хат килеп керде. Шулар белән таныштым да...

— Кая соң ул хатлар? Кемнәр яза, ни турында язалар?

— Әйтәм ич, Дәүләтъяров хакында язалар, причем ышандырырлык итеп язылган ул хатлар. Татарча булгач, тәрҗемә итеп бирделәр. Хатларның эчтәлеге белән танышып чыккач, җанның тынычлыгы китте, фактлар кызыклы гына. Берсен Кәрим Хәрәмуллин дигән кеше яза — ул Дәүләтъяровның авылдашы, аның сәүдәгәр малае булуын хәбәр итә. Анкетада Дәүләтъяров үзен батрак дип күрсәтә. Алдашу налицо, иптәш Мөхәммәтҗанов. Икенче хат — аноним. Хат язучы дәлилләп Дәүләтъяровның күрә торып милли кадрларга өстенлек бирергә маташуын күрсәтә. «Кызыл Татарстан»да эшләгәндә тәнкыйть материалларын бирдертми үзәкләренә үткән журналистларның. Моңа да мисаллар бар. Өченчесе — Минзәлә, Буа якларында партия эшләрендә кайнаган Шәмтиев дигән иптәштән. Ул Дәүләтъяровның коллективлаштыруга ышанмавы, аңа каршы булганлыгы хакында хәбәр итә. Җиттеме?.. Нәрсә, тагын Абрамов, Байчурин чорына кайтабызмы?..

Мөхәммәтҗанов исәңгерәгән хәлдә тора бирде. Әлеге мәсьәләгә үзен дә шартлатып бәйләп куярга мөмкин икәнлекләрен яхшы белә иде ул.

— Нәрсә дип әйтергә дә белмим. Фактларны тикшерергә кирәктер башта, иптәш Алемасов. Ашыгып, тастагы су белән баланы да тышка чыгарып түкмик.

— Ничек белмисең? — Алемасов тантана итә иде. — Фикердәшләр дисең ич. Фактлар раслансамы?! Син ни карадың, үзеңнең кадр бит, сорау синнән булачак!

Мөхәммәтҗановның тәне кызыша иде. Ул карашын идәнгә төбәде.

— Нишлибез, иптәш Алемасов. Минем өчен көтелмәгән хәл булды. Әллә ничек...

— Оялмыйча миннән сорап утырасың. Нишлибез, имеш. Хатларны Михайловка тапшырам, тикшерсен! Ә син бу сөйләшү хакында шым бул. ТЭЦ икән ТЭЦ, эшләрбез, юкка борчыласың, Мөхәммәтҗанов!

Михайлов күптән түгел генә НКВД наркомы итеп Та-

тарстанга җибәрелгән, Тулада «халык дошманнары»н фаш итүдә гаять тырышлык һәм өлгергәнлек күрсәткән кеше. Мөхәммәтҗановның астына су кергәнен сизенеп, кызара-бүртенә әлеге вазгыятьтән чыгу юлын эзләп азаплануын күзәткәндә, Алемасовның уенда бер генә нәрсә иде – разнарядкадагы өч-дүрт мең дошманның икесен ул инде төгәл белә, калганын вакыт хәл итәр...

## VIII

Көз айлары тынгысыз булырга охшый...

Советлар Союзы дип аталган биниһая зур, төрледән-төрле кавем, ил-гавамнан укмаштырылган корама дәүләт 1936 елгы Яңа Конституция нигезендә СССР Югары Советына яңа сайлауларга әзерләнә иде.

Халык хөкеменә чыгарылырга тиешле кандидатураларның исемлеген булдыру, республиканы сайлау округларына бүлеп чыгу белән башлар катты. Бу эшләр ТатЦИКка йөкләнгән булса да, бер генә эш тә ХКС рәисе Дәүләтъяров катнашыннан башка үтми, чөнки һәрнәрсәгә акча, транспорт, башка төр чыгымнар кирәк, хөкүмәт масштабындагы чараларга турыдан-туры ул җавап бирә иде.

Кич соң гына өйгә кайтып керә ул, иртәгәге көнне исә әллә ничә киңәшмә үткәрергә кирәк, төн йокламый шуларга әзерләнеп утырмый чара юк, иртүк кабинетка килеп керергә өлгерми, Алемасов чакырып ала да бер олау эш йөкләп чыгара. Барысы да тиз кирәк, барысы да «срочно»! Әзерләп кенә өлгер. Шушы тиен тәгәрмәчендә әйләнгән арада көннең үтеп китүен дә сизми кала, җиргә караңгылык иңеп, төн җитеп килә икән инде, сыгылган лимон кебек өенә кайтып кергән була... Иңдә бер олау эш ияреп кайта...

Шул кәгазьләр белән әвәрә килеп таңга кадәр утыра. Яңа эшкә керешкәннән бирле вакытны тоймый башлады Әхмәтсафа. Тагын бер нәрсәне шәйләп алды, аңа Алемасов ничектер сәер карый кебек. Эш мәсьәләсенә килгәндә ышаныч күрсәтә, ә башка нәрсәләр хакында ачылып сөйләшкәне юк аның белән. Чит итә, ят күрә. Мөхәммәтҗановның да соңгы көннәрдә аның белән сөйләшеп-киңәшләшеп утырырга вакыты юк. Киеренкелек торган саен көчәя, бер як та, шик-шөбһәләрне читкә ташлап, ачыктан-ачык сөйләшүгә бармый. Бу хәлдән дә яман нәрсә юк икән, кешеләр күз алдында үзгәрәләр, бөтен ил, җәмгыять ниндидер сәер авыру белән сырхаулый, әлеге чиргә дару табылуы да шикле. Дәртсез, дәрмансыз яши халык.

Бүген дә көннең ничек үтеп китүен сизми калды. Өйгә кайтып, шул эш-мәшәкатьләр, җанны бимазалап торган борчулар хакында уйланып утыра торгач, ярты төн үтеп бара икән менә.

Бертын башын ял иттерергә теләп, карашын өстәлгә тара-

тып ташланган кәгазьләрдән күтәреп, бераз уйланып алды. Иртән Алемасов янында булуы, аның кинәт Усманов хакында төпченә башлавы истән чыкмый, бу сөйләшү төбендә нидер ята, ул әлегә чамалап кына бетерми, ахры.

Табигый, Шамил Усманов турында тыныч кына уйлый алмый ул. Кулга алынып, төрмәгә ябып куелуы һич башына сыймый. Шундый зур пост биләп тә аңа ярдәм итә алмавына вөҗданы кыйнала, теңкәгә тия, Усмановны ничек кенә гаепләмәсеннәр, һич тә «халык дошманы» итеп таный алмый, бәлки, әдипне саклап калырга мөмкинлекләр дә булгандыр, бәлки әле дә соң түгелдер... Әмма дә ләкин курку хисе җиңде — бу хакта сүз башларга ничә мәртәбә талпынып караса да, кыюлык дигән нәмәрсәнең канатлары тиз салынып төште, хәтта үзе ярыйсы гына яхшы белгән, дошман булуларына һич кенә дә ышана алмаган бер генә язучы язмышын җиңеләйтү турында сүз башлап, күңелендәге шикләрен Алемасовка авыз тутырып әйтергә җөрьәт итмәде. Аны, халык комиссарлары рәисе Дәүләтъяровны, формаль яктан карагында, республикада икенче дәрәҗәдәге кеше дип исәпләргә буладыр, ә менә яңа гына Татарстанга борын төрткән Михайловны — НКВД наркомын үзеннән күпкә көчлерәк, куәтлерәк итеп тоя. Әле Алемасов белән ике арада, бигрәк тә соңгы көннәрдә моны ачык сизә ул — Дәүләтъяровның һәр адымын контрольдә тотучы Мөхәммәтҗанов та бар бит. Галим ачыктан-ачык әйтте, Дәүләтъяров аның белән киңәшләшмичә Алемасов ягына сыңар адым да атларга тиеш түгел!

— Безнең аста казыналар, брат, сак булырга кирәк. Нишләсәк тә, бер-беребез белән хәбәрләшеп, киңәшеп эшлик. «Теләрнең» бер генә кыланмышларына да вак-түәк дип карама. Затсыз адәмнәр болар, күзләрендә иман нуры юк...— дип кисәтеп кенә тора Мөхәммәтҗанов.

Алемасов исә, Галимнең ни уйлаганын сизенгәндәй, киресен сукалый.

— Мине бер дә яратмыйсың бугай, Дәүләтъяров,— диде ул бер киңәшмәдә, өлкә комитеты әгъзалары янында кәперәйгән кыяфәттә.

Казанга килгәч тазара төшкән Алемасовның нурсыз чыраена, тар маңгай астыннан дөньяга җирәнеп караган чепи күзләренә, шыксыз кулларына мизгел эченнән караш ташлап өлгергән Әхмәтсафа ни дип әйтергә дә белми интеккәндә, Беренче йөзендә арзан елмаю җәелде.

— Миңа үчлекле карап торасың кебек, шуңа әйтәм яратмыйсың дип.

Кылтаеп, фахешләнеп үзенә кадалган Алемасовка җавап бирергә өлгермәде, Мөхәммәтҗанов «ярдәмгә» килде:

— Ярату-яратмавын үзе белә, әмма Сезне хөрмәт итә, моны барыбыз да күрәбез.

— Яратмый, хөрмәт итә... Шәп әйттең, Галим Мөхәммәтҗанович, сез инде ике дус, бер-берегезнең ни уйлаганын яхшы беләсез, мин сиңа ышанам,— дигән булып, котсыз кеткелдәп алды. Янә чепиләнеп халык комиссарлары советы рәисенә төбәлде.— Шулай да, Дәүләтъяров, кайбер нәрсәләрне минем белән беренче чиратта киңәш итәргә кирәк. Читләшмә, мин бит кеше ашаучы бүре түгел!

Юкка гына барысы алдында аны яклау ягына басмады Галим, нидәндер шикләнә, нәрсәдер белә, әйтеп бетерми. Үзен Алемасов тирәсенә җибәрергә тырышмавын ваклану яки көнчелектән түгел икәнен яхшы аңлый, сәбәпләрен төшенеп кенә җитә алмый. Шул ук вакытта Мөхәммәтҗанов үле җан түгел, карьерасы хакына бернәрсә белән дә хисаплашмаучы кеше икәнен дә чамалый, бу мәсьәләдә, Алемасовтан кала, теләсә кем белән теләсә нинди бәхәскә, хәтта интригага да барырга әзер кеше. Мондый шартларда нишләргә аңа? Республиканың хуҗалык сәясәтен үзенчә алып барырга омтылу куркыныч хәзер. Ныклап киңәш-табыш итәрлек кешеләр кими бара. Әхмәров та, Алемасовның ул чакта аңа бәйләнеп азаплануын начар фалга юрап, аннан читләшә бугай. Һәр дәһри коммунистның күңеленнән көнгә мең мәртәбә кабатлаган догасы: «Аллаһ сакланганны саклармын, дигән инде, безләрне Ходай үзе сакласын, уйламый-нитми дию авызына килеп керә күрмик, ярабби Ходаем, яман күзләрдән, яман уйлардан, яман гамәлләрдән саклап йөртә күр!»

НКВД да йоклап ятмый, сизеп тора — һәр адымы күзәтү астында. НКВД наркомы белән аңлашу табарга омтылыш ясаса?.. Юк, аның Михайловка теше үтмәячәк. Аның гына түгел, Михайлов белән Алемасов та үзен сак тота, башкача сөйләшә, Мөхәммәтҗановны инде әйтеп тә торасы юк, һәр сүзеннән, хәрәкәтеннән, ымыннан Михайловтан куркуы шәйләнә.

Мөхәммәтҗановка кереп, барысын уртага салып сөйләшергә дисәң, анысы да хәвефле кебек. Икенче ТЭЦ хакында сөйләшкән көнне иртән, Алемасовтан чыгып килгәндә, каршы очрады ул. Күптән сагынып көткән очрашу мизгелен кичергәндәй балкып килеп күреште, хәл-әхвәл сораша башлады. Алемасов кабинеты ягына күз сирпеп алгандай итте.

— Сине дә тындырмый Беренче, миңа да тынгы юк. Кабинетка керергә өлгермәдем, чакырта да башлады,— дип зарланып та алды. Гомумән, шулай эш күплектән җәфа кичергән кеше сыман, үз күргән кешеләренә зарланырга ярата иде ул...

— Күптән көтелгән сөйләшү — кичекмәстән хәл итәсе бер мәсьәлә бар иде,— диде Әхмәтсафа, капчыкны төбеннән селкисе килмичәрәк.

Мөхәммәтҗанов сагаеп калды.

— Нинди мәсьәлә ул?

— Син аны яхшы беләсең, бу турыда сөйләшкәнебез бар — ТЭЦта төзелеш эшләре бик әкрен кыймылдый, шул эчне пошыра. Төзелешне туктатып, аңа каралган акчаны башка тармакка җибәрергә дигән карашлар да бар иде.

Икенче секретарь кайнарланып сүзгә кушылды:

— Өлкә комитет әгъзаларыннан ТЭЦ төзелеше өчен җаваплы итеп мине билгеләгәннәр иде. Аңа мин кураторлык итәм... Кайда авыр, кайда провал, шунда мине китереп тыгалар, үзең беләсең. ТЭЦ белән дә шундый хәл сизелә. Эшнең торышы хакында бик беләсе килә, соңгы вакытларда күрә торып аннан читләштерәләр, нәрсә барганын да аңлый алмыйм. Инде дә килеп, бер-бер нәстә килеп чыкса, гаепләне тиз табачаклар... Галимне бүген тотып ашарые кайбер адәмнәр.— Кызыксынып, сорау бирде.— Нәстә ди соң Беренче?.. Мәсьәләнең очына чыга алдыгызмы?..

— Туктатмаска дигән карарга килде.

Мөхәммәтҗанов кулындагы папканы җилпеп алды.

— Шәп бу, иптәш Дәүләтъяров! Күпме көннәр эчем пошып йөри иде шуңа. Моннан соң да бер-беребезне подводить итмик. Әйтәм бит, шул нәстә исемә килеп керсә, төн йокыларым кача дип. Тоттылар да миңа сылап куйдылар, таптылар бер Архимед тәпәчен, кайда нинди йөк ята, шуның астына мине китереп тыгалар, шуннан йөк кузгатырга тиеш ди мин!

Сөйләшү шунда өзелде, аны сәркатип, чираттагы киңәшмә башланганчы, Алемасов янына кереп калырга ашыктыра иде.

Әхмәтсафа, уйларын читкә куып, янә кәгазьләренә иелде.

...Эшкә мавыгып күпме утырыр иде, билгесез, кинәт урам якта, тәрәзә артында гына бер адәмнең ачы тавышы ишетелде:

— Коткарыгыз, талыйлар, үтерәләр!..

Әхмәтсафа эшен бүлеп, тәрәзәгә капланды. Тышта караңгы, кар катыш вак яңгыр сибәләп тора. Урамнан кемнәрдер йөгереп үтеп, куыша-куыша күрше ишегалдына керделәр бугай — тавышлар шунда ишетелә. Икеме-өчме кеше бер адәмгә бәйләнәләр булса кирәк: әллә талыйлар, әллә кыйныйлар.

Бәлагә таручының ара-тирә:

— Коткарыгыз, үтерәләр!..— дип өзгәләнеп кычкырган тавышы кабатланып ала. Күрәсең, тиз генә берешә торганнардан түгел, җан-фәрман тартыша сыман.

Ул кисәк кузгалып, кием элгеченнән кәчтүнен эләктереп алды да урамга атылды. Артыннан Рабиганың аптыраулы-куркулы тавышы ишетелеп калды:

— Төн уртасында кая барасың?.. Урамда кем ни кыланмас. Йокларга ят, иртүк эшкә барасыңны онытма...

Хатынына җавап биреп тормады. Урамга йөгереп чыкты. Баганаларга эленгән лампалар өй тирәсенә бераз яктылык сирпесәләр дә, тавыш килгән якта дөм караңгы. Теге

бичара һаман карыша, тартыша бугай, колакка: «Ярдәм итегез, ярдәм!» — дигән сүзләре ишетелеп киткәли. Ләкин баштагы кебек ачы тавыш түгел, еламсыраган, чарасыз ялвару гына иде инде бу. Шәһәр уртасында түгел, бәлки кайдадыр кешесез урманда, чытырманлы сазлыкка кереп баткан бичара адәмнең өметсез тыпырчынуы сыман тоела.

Әхмәтсафаның таләпчән һәм икеләнүгә урын калдырмаслык куе тавышы төнне ярып үтте:

— Туктагыз, хәзер үк туктагыз — теленә каян килгәндер, — атам! — дип тә ычкындырды. — Ике-өч адым атлауга, сизми калды, көрмәкләшкән кешенең берсе кул астына килеп керде, аны сөйрәп торгызды да, үзен белештермичә, әллә кая ук болгап ыргытты. Чамалап өлгерде, әзмәвердәй адәм иде бу. Бик каты барып төште бугай, чинап, сикереп торды һәм, бу якка борылып та карамый, сүгенеп урам якка йөгерүен шәйләп калды. Эченә җылы керде, чыннан да каты тавышлы кешенең ату коралы бар дип уйладылар, ахры. Ул арада аңа бәрелеп-сугылып тагын бер кеше капка ягына атылды. Аның артыннан ташланмакчы иде Әхмәтсафа, кире уйлап, җирдә мышкылдап яткан бичара бәндәгә иелде:

— Ни булды, иптәш?

Теге кеше, исенә килеп, еламсыраулы калтыранган тавыш белән җавап кайтарды:

— Таладылар, башлары култык астына киләсе сбулычлар... Бөтен акчамны, өстәге киемнәрне алып ычкындылар, паразитлар...

Ул мәрәләп аягына басты, сизелеп тора, ярыйсы гына «чирттереп» алган бу мәхлук. Читкәрәк тайпылган Әхмәтсафаның җиңеннән эләктереп алды:

— Абзый, зинһар, ташлап калдырма инде. Бишбалта ягына кайтасым бар бит... Почмакта качып көтеп торалар алар, беләм, мине тәмам чишендереп бетерәсе килә аларның... — Ул череллдек тавыш белән сүгенеп алды.

Ни гаҗәп, Әхмәтсафага әлеге тавыш таныш сыман тоелды. Әллә бу кешегә ярдәм итү теләге, әллә кызыксынуы көчле булды, бәлагә таручыны өйләренә табан алып китте. Шул чагында гына үз өенең капка төбендә серәеп басып торган каравылчыны шәйләп алды.

— Нишләп чуләндәй басып торасың, понимаешь? — дип, ачулы тавыш белән сорау бирде Әхмәтсафа. — Каршыңа килеп, кеше кыйныйлар, талыйлар, чишендерәләр, ә син?..

Каравылчының җавабы әзер иде:

— Миңа, иптәш Дәүләтъяров, шушы өйне, ихатаны сакларга кушылды. Өй эчендә ни-нәрсә бар, хуҗалар кая чыга-керә, анысы өчен мин җавап бирмим, — диде сакчы, гөнаһсыз тавыш белән. — Әгәр сезнең ишегалдында булса бу хәлләр, мин чарасын күрә идем, әлбәттә, ә болай бөтен шәһәр өчен минем җавап

бирәсем юк... Шулай да мин, иптәш Дәүләтъяров, сезнең арттан бардым. Инструкцияне бозып булса да... Сак урынын калдырырга ярамый безгә. Бандитның берсен сугып кына очырдыгыз бит, тегеләрнең нинди тизлек белән ул тирәдән таюларын үз күзем белән күргәч, тизрәк сак урыныма йөгердем. Гайрәт тә бар икән, иптәш Дәүләтъяров, үзегездә.

Җавап күңеленә хуш килде, Әхмәтсафа сакчының иңсәсеннән кагып алды:

— Без, үзебезне ир-егеткә санаучылар, кирәк чакта кешегә ярдәм кулы сузмасак, ни була? Менә бит, күзге күн дип тормаганнар, иптәшне чишендереп киткәннәр...

Бәлачел тавышлы мәхлук сүзгә кушылды:

— Итеккә кадәр салдырып алып киттеләр, кабихләр.

Өйгә кереп, кухняга үтүгә, ут яктысында Әхмәтсафа төнге «кунак»ка текәлеп караган иде, имәнеп китте — аның каршында шәлперәеп авылдашы — Кәрим Хәрәмуллин басып тора иде. Авызы бүлтәеп чыккан, ирен читеннән кан саркый.

— Кәрим? — дип, гаҗәпләнеп, телгә килде Әхмәтсафа. — Кәрим... Хәрәмуллин! Син түгелме соң бу?

Төнге кунак лыпылдап идәнгә утырды.

— Соң, ни... Кара инде... Тинтәк димә... Әхмәтсафа бит син, зур кеше... — дип тәтелдәргә тотынды Кәрим. — Ишеттем... Кем сун әле син? Юк инде, башка ару сукканнар теге сбулычлар, һич кенә эшләп китә алмый менә, — дип сөйләнде ул, исән калуына бер сөенсә, Әхмәтсафа кулына килеп эләгүенә ун мәртәбә артык шатланган кешедәй. — Каравылчыны әйтәм, «Иптәш Дәүләтъяров, иптәш Дәүләтъяров» дип бер алдыңа, биш артыңа төшеп тора югыйсә, ә мин нуль внимания, әйеме. Әхмәтсафа, эт талагыры, син бит бу! — Кәрим урыныннан сикереп торып, коткаручысын кочакларга ниятләп, алга атлады. Борынына килеп бәрелгән сасы көмешкә исеннән, Әхмәтсафа ирексездән читкә тайпылды, теге, моңа әһәмият бирмәгәндәй, һаман сөйләнә, һаман якыная:

— Әйе, мин инде бу Кәрим Хәрәмуллин. Каргалыдагы күршең булам... Бергә уйнап, күңел ачып үскән Әхмәтсафакаем, туганымнан артык кеше бит син! Ничекләр килеп чыктың мине араларга?!

— Каян килеп чыктың монда? — дип, арган тавыш белән сорады Әхмәтсафа. Нигәдер үзе коткарган кешенең Кәрим булуына тамчы да сөенмәде кебек. — Йөрисең төн уртасында разбой салып...

— Күрәсе башкайлар булгач, Әхмәтсафа күршекәем, килеп каптым инде. Шушы эт олаккан җиргә килергә нинди шайтан котырткандыр. Кичә зарпылат алган идек, мин бит җир төзү техникумын тәмамладым, Казанга килеп. И дөрес эшләгәнмен, иеме, күршекәем. Кая бакма төзелеш, бездән башка

бер генә эш тә башланмый, акча мулдан түләнә, шуңа кылтаеп киткәнмендер инде, эштән соң өйгә кайтмый, бер марҗаның итәгенә ияреп киткәнием, утырылган бит менә, шул тәрегә алданып. Кесә тулы акча, кәеф әйбәт, марҗага өмет тә бар иде, хәйләкәр кәнтәй булып чыкты. Төн уртасына кадәр минем акчага кибеттән ризык ташыды, имеш, мине сыйлый, сасы самагунын чөмертте, анысын да акчага сатып бирә, заразы. Шулай утыртты-утыртты да, дәртем тулышкач кына: «Ирем кайтыр вакыт җитте»,— дип, артка тибеп чыгарды, мөртәт. Ишегалдынннан чыгып өлгермәдем, ике кеше килеп бәйләнделәр... Ярый әле кычкырырга баш җитте. Акчадан җилләр исте. Шунысын гына аңышып бетермим, акчаны кем алды микән, марҗамы, әллә теге бандитлармы? — Кәрим, җилкенеп, Әхмәтсафаның кулын эләктереп алды: — Әйдә әле, сакчының мылтыгын алабыз да, Әхмәтсафа күршекәем, теге марҗаны өшкереп, иманга китереп кайтыйк. Мин мәлҗерәп йоклап киткәч, үзе генә оештырган ул бу эшне... Шурасын нәсел-нәсәбен әрдәнәләп өеп өшкерим. Шура исемле ул. Беләсеңдер әле үзең дә, күршеңдә генә яши ич, бә-әк чибәр нәмәрсә. Ямьсез булса, Кәрим тагылып йөрми инде ул. Мин хатын-кызның билен карыйм, аннан түбәнгәрәк күчәм, артын күз белән капшап узам. Ботын чамалыйм...— Кәрим монда ничек килеп эләккәнен онытып, сиптерә генә.— Хәхә, опыт бар, күрше, тырнаклы егет мин. Күңелгә ошаса, җәһәннәмгә дә китәргә риза тутый кош артыннан...

Өйдәгеләрнең йокылары качты, шуңа кыенсынып, Әхмәтсафа Кәримгә ике-өч кәлимә сүз ыргытты.

— Туктат юк-бар әкиятеңне, шул гына җитмәгән иде. Әйдә, юын, кайнар чәй эчеп ал, калганын иртәгә эшеңдә сөйләрсең, тыңлаучы табылса...

—囗Эштә моның ишене аңлаучы бар дисеңме? Җыен мокыт бездә, хатын-кыздан уттан курыккандай шүрләп йөрүчеләрне китереп тутырганнар. Барысы өчен тутыйларның күңелен үзем күрәм, авырга килә, кәнишне, ну түзәм! — Исенә килеп, хуҗага ялагайланып сөйләнә башлады. − Син, Әхмәтсафа, бигрәк тә тәртипле, игелекле кеше булдың инде. Рәхмәт, коткардың, бандитлар кулыннан үтәсе идем бүген төнлә... Мин шулай инде, эчемдәге — тышымда, син элеккечә, сүзгә саран, үзең турында ләм-мим сөйләмисең. Ә-ә, Кәрим Хәрәмуллин белми ди торгансыңдыр инде, белә-әм, зур кеше булдың, гәҗитләрдән укып торам, — Кәрим кыланып кулын болгап алды.— Халык комиссарлары советы председателе иптәш Дәүләтъяров!.. Синең турында язган гәҗитне саклап, чумадан төбендә тотам, ә кәк же, күршең шундый урынга үрмәләсен әле! Бер кирәк булмаса, бер кирәге чыга. Әткәй әйтә минем, тутыгып беткән балтаны да чыгарып ташлама, б... чабарга булса да ярар, ди. Син инде балта гына

түгел, юк, балта пүчтәк ул! Менә бит Каргалыда чакта, ТИНОда укыганда кем уйлаган? Ачу да саклый торгансыңдыр, әеме? Фатыйх Сәгыйтов котыртуы буенча каныңа тоз аз салмадым мин, әйеме, күршекәем, ачуланма инде. Ничек шулай була микән? Мин дә укыдым ТИНОда, син дә укып йөрдең. Син кем дә, мин кем? Кызык бит, әйеме, күршекәем. Ераклашканбыз, ара зур, мин әйтәм, югыйсә ким дигәндә, безнең ара бер адым булырга тиеш иде. Баксаң, җир белән күк арасы — син нинди фатирда яшисең, мин бер эт алачыгында көн күрәм.— Кәримнең көнләшүе йөзенә бәреп чыкты, шулай да үзен кулга алды тагын.— Син инде элеккеләрне искә төшереп, кинә саклап йөрмә, күршеләр бит без. Күп сөйләшкәнгә дә ачуланма, мин бүген чакырылмаган кунак, әткәй әйтә, чакырылмаган кунакның хакы күбрәк аның, ди.

Кәримнең, үчекләгәндәй, кат-кат атасын телгә алуы Әхмәтсафаның бәгыренә ук сыман кадала. Рәнҗү хисе җанын каерып-туздырып ташлый, тешен кысып булса да, сабыр итә, «әткәй» дип сөйләнүләрен колак кырыеннан үткәреп җибәрергә тырыша иде.

— Нинди кинә ди инде, үткән эшкә салават... Озакламый таң ата, иркенләп гәпләшергә вакыт кысан, шул гына.

— Таң, дисең инде... Таң ата да кич була, хәерсез таңнар бу, күршекәем, хәерсез таңнар, әткәй әйтмешли... Күңелгә нур салып атмый таңнар минем, күптәннән инде, теге янгын чыккан көннәрдән үк. Фатыйх Сәгыйтов дигәннән, хәзер кайда эшли микән ул? — Кәримнең күзләре сәер елтырап китте.

— Кайда булсын, һаман да газет эшендә. Редакциядә. Газет укыйм дип мактанып торасың, җитмәсә. Таңга килсәк, аның нуры үзен сыйдыра алган күңелгә генә кереп туладыр ул. Күңелең тар булса, анда нурга, яктылыкка урын калмый.

— Юк, син һаман элеккечә, Сафа, өнәп бетермисең мине. Гәҗитне укыйм ла анысы, үземә кирәген генә укыштырам, калганына вакыт җитми. Фатыйхның адресын бир әле, гәҗитеннән бер урап кайтырмын, яшь вакытларны искә төшереп утырсаң да, күңелгә җиңел була бит ул. Мусаны күргәнең бармы соң? Мәскәү егетенә әйләнеп беткәндер ул, әйеме... иптәш Дәүләтъяров.

Әхмәтсафа Кәримнең «иптәш» дип сөйләшүен килештермичә җавап бирде.

— Төн уртасында «иптәш»ләп утырмыйк. Эш урыны түгел. Муса исә, молодец, танылган шагыйрь хәзер. Әле опера студиясендә белем алдылар, Казанга кайтырга җыена.

— Опера? Ниемә кирәк ул? — дип, Кәрим балаларча аптырап сорады.— Радиодан ишетсәм, колагым тона шул опера дигән нәрсәдән. Бөтен Казанны шул опера белән тутырмакчы буласызмы тагын, Дәүләтъяров, ә?! Ниемә хаҗәт ул? Сәгатьләр буе шуны тыңлап утыра башласаң, төзерсең

яңа тормыш, төземи. Социализм фронтында кем эшләр, ә? — дип чәпчеп алды Кәрим.

— Менә Фатыйх Сәгыйтов янына барып чыксаң, аңлатыр ул сиңа, — дип көлебрәк җавап кайтарды Әхмәтсафа. — Берзаман бу мәсьәлә буенча шау-шу булып алган иде, опера сәнгатен яклап Сәгыйтов мәкалә язып чыкты, ну Мусага да тәнкыйть эләктерде. Муса миңа хат та җибәргән иде. Бераз үпкәләгән, кәнишне, ул чакта газетада мин редактор идем.

— Фатыйхның теленә эләксәң... Кислота бит ул! — Кәрим сүзне шундук икенчегә борды. — Шулай да әйт әле, Әхмәтсафа, ничек зур кеше булып киттең син? Артыңнан этеп торучы бармы? Менә мин дә эшлим бит инде, тырышам, тырмашам, кеше арасына керәсе килә. Юк, гел читкә кагалар. Берсенә бер начарлык эшләгәнем булса икән. Ипекәй, кеше белән сүзгә килешкәнем юк, җитешсезлекләр хакында нәчәльствәнең үзенә язып кына бирәм, имзамны да куймыйм, үзе өчен тырыша димәсеннәр, әйеме, алар бит ахмак түгел, кем язганын чамалыйлар, фактта — минем шулай эш өчен ут йотып йөрүемне, социалистик уяулыгымны күрмәмешкә салышалар. «Кәрим Хәрәмуллин әйбәт эшли, дошманнарга пакуй бирми» дигән бәләкәй генә кәгазь тоттырсалар, күңел булыр иде, анысы да юк безгә. Кешегә күп кирәкмени?

— Кешенең зурлыгы кайда эшләве, нинди пост биләвенә карап үлчәнми, Кәрим дускай. Иманыңны сатма, кешегә начарлык кылма — шуннан чыгып бәяләнә адәм баласының гамәле.

— Сүз сөйләргә сиңа куш инде. Кара әле, Фәтхулла абзый турында ишеттеңме син? Теге ат буры. — Кәрим кисәк Әхмәтсафага күтәрелеп карап алган иде, аның күзендә уйнап алган ачулы очкыннар күреп, шым гына сүзен төзәтеп куйды. — Фәтхулла абзыйны белмәскә инде син. Каргалыда бергә көн иттегез бит. Үткән җәй аның белән очрашып, озаклап сөйләшеп тордык.

— Фәтхулла абзый? — Әхмәтсафа пыяла стаканга чәй коя иде, туктап калды. — Каян килеп очраштыгыз әле аның белән? Ниһаять, үзебезнең якларга кайтып элгәшкән икән.

— Оренбурга кайтып урнашканнар иде Шәмсия апай белән. Милициядә эшлим дигәч, күзләр маңгайга менде. Шул ат буры... — Бу сүзгә Әхмәтсафаның ачуы кабарганын сизеп, Кәрим сүзен төзәтеп дәвам итте. — Болай гына, элекке гадәт белән әйтүем, авылдаш булгач, озаклап сөйләшеп торган идек. Казанга эш белән барасым бар, сине бик күрәсе килеп, сагынып телгә алды; нигә кирәк булгандыр, әткәй турында озаклап сорашты. Әткәйгә әйткән идем, бер дә яратмады аның шулай сорашуын. Әткәй минем бик честный бит, ат буры булган кеше милициягә кереп, наган тагып йөргәч ни. Фәтхулла агай сине әй яратып та сораштырды инде,

сәлам дә әйткән иде, мең рәхмәт төшкере, әманәтне үтәргә җай чыкты.— Кәрим ниндидер тонык тавыш белән дәвам итте.— Кара әле, Фәтхулла абзый ул чакта нигәдер озаклап минем әткәй хакында төпченде. Теге чакта суга төшкәндәй юкка чыкты бит әткәем... Шикләнеп сораштырды микән?.. Яшүсмер генә идем, бернәрсә белмим дисәң дә ярый, түлке интектек тә соң әткәйсез калып. Әллә ничек кенә булды, әнкәй дә җүнле-башлы әйтеп, аңлатып бирә алмады. Өченче ел әткәй тып итеп кайтып кергән өйгә. Картайган, шулай да исән-имин. Кайда булган, кайларда йөргән, бер дә сөйләми. Әллә Фәтхулла абзый бер-бер нәрсә беләме дим, озак уйлап йөрдем. Шунда сорарга башка килмәде. Ничек килсен, минем башның күргәннәре. Эчсәм, холыксыз бит мин, Әхмәтсафа күршекәем, хатынга бәйләнәм. Хатын бик әтчәяннәй нәрсә, бәйләнә башласам, ике дә уйламый, чүмеч белән башка тондыра. Мин өч көн исәнгерәп, өйгә юл тапмый саташып йөрим. Баш җиде җирдән тегелгән минем, хәзер эчеп кайтсам, чүмечне яшереп куям.— Кәрим тагын сүзен Фәтхулла абзый ягына борды. Әхмәтсафа, ни сәбәп, тынын алмый диярлек, кызыксынып тыңлый бирде.— Әткәй килештермәде, юк кына менә, килештермәде Фәтхулла агайның сорашуын. Ничек килештерсен, ат буры милиция булсын инде, егылып үләрсең...

Кәримнең шушы сүзне әйтмичә, тынычланмаячагы билгеле иде. «Алтыдагы — алтмышка», бу кеше белән шулай көтмәгәндә очрашуына Әхмәтсафа үкенеп бетә алмый иде. Аның каршысында әтисенең үлеменә сәбәпче авылдашының малае, ТИНОда чакта яла ягып, башын әйләндереп бетергән бер бәндә тора, ни әйтергә аңа, ничек озатырга өйдән үзен?..

Шулай да кабарган ачуын басып, үзен кулга алды. Кәрим чыннан да әтисенең нинди явызлык кылганын белми иде булса кирәк. Әтисе кылган явызлык өчен бала җавап бирми.

Йокы бүлмәсеннән чыгып, Кәримгә аптырап карап торган Рабигага эндәште:

— Сабакташны таныйсыңмы, Рәбуш?

Кәрим урындыктан егыла язды.

— Рабига?! Сез тәки өйләнештегезмени, эт талагырлары!

Рабига, бу шәүкәтсез кешедән котылырга теләп, теләмичә генә сүзгә кушылды:

— Кәрим Хәрәмуллин тиз генә истән чыга торган кеше түгел инде. Таныйм, билгеле. Син Урта Азиядә чакта мин Каргалыда укытып алдым. Анда да тинтерәтеп бетерә иде җыен юк-бар белән...

— Әй бу хатын-кыз! Әллә ниләр сөйләп бетермә инде, Рабига, яшь чак бит, кызлар күрсәм, бераз кылтаеп киткәнмендер. Аннан синең арттан ул чакта Муса чапты түгелме соң? Ике көннең берендә Каргалыга прусты гына килмәгәндер инде. Комсомол активлары арасына кысылып йөрү килешмәсә дә,

безнең авылга килгән чибәр кызны Муса эләктерергә чамалагач, ачу чыкты, бер-ике мәртәбә кич нардумнан кайтканда, каршыңа чыгып, бәйләнеп торган булган идем. Шуны сүз итеп сөйләгәнең өчен рәхмәт... Ирең көнләшер дип тормыйсың...

— Әхмәтсафа синнән көнләшә диме?.. Кит инде, тавык көлдермә!

— Мине кешегә санамыйсың инде, анысын беләм, Рабига. — Кәрим, үзенең хәлен онытып, зәһәрләнеп үчләшә иде. — Мусадан да көнләшмисеңме, Сафа?!

Әхмәтсафа сүзгә нокта куйды.

— Көнләшмим! Мусаның үз гаиләсе бар. Үзең әйткәнчә, яшь чактагыларны искә төшереп утыра башласак, барып чыгарбыз. — Ул һаман да ачуын баса алмаган хатынына эндәште. — Бәлагә тарыган бит әле Кәрим, кыйнап, чишендереп киткәннәр. Бүген бездә кунар, искеләр булса да, җүнлерәк киемнәр бардыр, киендерик инде үзен. Шәрә килеш кайтарып җибәреп булмый.

— Дөрес әйтәсең, килешми безнең ише кешегә болай йөрү, — дип такылдап алды Кәрим.

— Киеме табылыр, — диде Рабига, бераз сүзсез торганнан соң. — Йокларга урын әзер, залга кереп ятсын. — Ирен шелтәләп алды. — Таң ата бит инде, иртәгә ничек эш көнен үткәрерсең?..

Кәрим озак йокламады, черем итеп алды микән, бераз боргаланып ятты да, торып, китәргә җыена башлады. Әхмәтсафа торып, ут кабызды.

Киемнәрне Рабига барлап куйган икән, Кәрим аһылдый-аһылдый аларны киеп, көзге каршысына басты. Нигәдер канәгатьсез тавыш белән:

— Ярый инде, киеп йөрергә булгач... — дип сөйләнеп, чыгарга кузгала башлады.

Әхмәтсафа аны озата чыкты.

— Интегеп йөрмә, — диде күксел тавыш белән Кәрим. — Юлны әйбәт беләм. Рәхмәт дисәң инде... Сез — зур кешеләр, төчеләнә белмисездер. Баш чатный, каһәрең, хатын төзәтергә җай табар анысы...

— Куй инде, рәхәтләнеп әйт рәхмәтеңне, — Әхмәтсафаның тавышы кинаяле иде. Күңелен кыздырып торган сорауны бирми булдыра алмады. — Шулай да әйт әле, Кәрим, Фәтхулла агай кайчанрак Казанга килеп чыкмакчы иде?

— Һаман аның турында уйлыйсың икән. Ишетмәгәнсең икән, миңа әйтергә туры килә. Килмәс инде ул Казанга. Быел җәй аның гәүдәсен Җаек буеннан табып алганнар. Элек бергә ат урлап йөргән кулдашлары хәл иткән, диделәр. Караклар арасында шундый тәртип, ди, башка якка чыккан кешене яшәтмиләр икән аны...

Әхмәтсафа өнсез калды. Уйлары чуалды, исәңгерәгән

хәлдә караңгы урам буйлап атлаган Кәрим артыннан озаклап карап торды. Офык ягыннан ал шәүлә йөгергәндәй булды. Таң ата иде...

## IX

Егерме тугызынчы ноябрь иртәсендә эшкә күңелсез уйлар эчендә килде ул. Фәтхулла агай турындагы хәбәрдән үзенә урын таба алмады. Кәримнең әтисе — җаһил карт, исән-имин кайтып, яшәп ята икән. Явыз, хөсет җанлы адәмнәр әтисе Мостафаны гүргә керттеләр, бер гөнаһсыз дөньядан киткән әткәсе исән калганнардан дога өмет итеп ята торгандыр. Әнкәсе белән әткәсе каберенә тезләнеп дога укып килергә дә вакыт тапма инде?! Бер генә атнага булса да, Каргалыга кайтып килергә иде. Эштә әвәрә килеп, аралар өзелеп бара түгелме соң? Туганнары — Гомәрхан белән Әхмәтхан, аларның гаиләләре белән күрешеп сөйләшергә, Бибкәй кияүгә чыккан, инде бәби дә алып кайтырга өлгергәннәр икән — яшьләрне котлап, бераз сөендереп киләсе булыр; хәзер менә күңелен тырнап торган нәрсә — Оренбурда тиешле кешеләр белән очрашып, Хәрәмуллин карт хакында дөресен сөйләп бирми чарасы калмады, шунсыз тынычлана алмаячак ул. Шәмсия әнисенең хәлен белергә, Фәтхулла агайның, агабзыкайның каберләрен яд итәргә... Ераклаша Оренбур аннан, ераклаша.

Ул, уйларын читкә куарга теләп, ян яктагы тәрәзә янына килеп басты. Күңел урыннан купкан, һич кенә үзен урынга утырырга мәҗбүр итә алмый. Кәримнең «хәерсез таң» дигән сүзләре хәтеренә килеп, җаны сискәнеп китте. Әй очынган булып яши ул, әй җилкенгән була, алда үзен ни көтә?.. Рабиганың тормышына бәреп кереп, бәллүрдән дә нечкә күңелле, саф, якты уйлы кызны бәхетле итәрмен дигән адарынулы хыяллары чынга ашамы?.. Яңа тормышның бар матурлыгын, мәртәбәсен күреп үсәргә тиешле уллары Марат белән Марлесны нинди язмыш көтә алда?.. Барысын да үлчәп, кат-кат уйлап эш итәме ул, әллә дәвернең тешле тәгәрмәченә ияреп, кая барып чыгасын чамалый да алмаган чарасыз тәгәрәүче бер җан иясеме?.. Мифтах хәлфә, патша төшерелеп, кан-яшь түгеп, илдә яңа хакимлек төзибез диючеләрнең эшенең ахыры ни белән бетәсен чамалый алмый ачынып, Дәрдмәнд шигырен көйләп алган иде:

> Үзең җирдә, күзең җирдә — ничек бу?
> Күреп күк дәфтәрен яндың, кабындың.
> Ни барын күрмәдең әмма юлыңда,
> Аяк астындагы ташка абындың!

Тәрәзәгә капланырдай булып, озак карап торды Әхмәтсафа.

Уртача гәүдәле, киң җилкәле, чигә тирәсендә чал чәчләр пәйда булган бу кешегә әле утыз ике яшь кенә тулып киткән икәнлегенә ышануы да кыен. Карашында ачык чагылган борчылу, җилкәсенә авыр йөк салынган булудан гына түгел, бәлки, чор тудырган галәмәт киеренкелек нәтиҗәсе иде. Казансу елгасына әкренләп боз ката, болай барса, елга аръягына халык турыдан гына чыгып йөри башлар. Әлегә бала-чага яр читендәге сайлыкларда ныгыган бозда тимераякта шуа, шар суга. Һәй, үтте-китте гомерләр, кая ул гамьсез чаклар, Сакмар буйлап Җаек тамагына кадәр тимераякта узышулар; беләкләрдә көч-куәт арткач, йөзләрчә чакрымнар сал агызулар. Ул чактагы борчу, тынычсызлыклар пүчтәк кенә булган икән.

Казан өстенә офыктан, Идел ягыннан калын, кара болытлар агыла. Көннәр кышка кереп бара, озакламый кар-бураннар башланыр, барысы да кар астында калыр, югалыр. Бүгенге җанны талап торган уйлар да, калын кар юрганы астында калгандай, тора-бара юкка чыгар, күңел түрендә юшкыны гына утырып калыр да ара-тирә искә төшеп йөрәк кыбырсып куяр. Чыннан да шулай булыр микән? Ил өстенә, аерым кеше башына ишелгән хәсрәт-борчулар да шулай онытылыр, йөрәккә сызылган җәрәхәтләре югалыр микән? Ай-һай, яшәү дигәннәрен артык гадиләштерәләр бугай алар. Яшәп баккан утыз ике яшендә ике гомер кичкән кадәр дөнья гизде, белем эстәде, төрле вазифалар башкарды. Дөнья буйлап бара да бара, нинди җилләр, нинди зилзиләләр иркендә ул, анысын ныклап торып уйларга да вакыт юк. Аяк астындагы ташка абынганчы барачак та барачак.

Тире-яры җыеп көн иткән Мостафа малае хәзер кем булды — хөкүмәт машинасында эшкә килә, көн буе зур-зур карарлар кабул итүдә турыдан-туры катнаша, һәр карар меңнәрчә кеше язмышына кагылып үтә, бу турыда ныклап уйланырга, фикер йөртергә дә өлгерә алмый кала бугай, чиратта икенче бер мөһим эш килеп баса, бусы инде, бәлки, меңнәргә түгел, дистә меңнәргә кагылышлы бер мәсьәләдер. Соңга калып өенә кайтырга кузгала, бүгенге эшен тәмам кылуын көтә-көтә көтек булган шоферы кайтарып куя, яшәгән йорты янында сак тора, ә күңел буш, шыр ялангач, күпләрнең төшенә дә кереп карамаган шушы уңайлыклар хакында уйлап тору да юк, баш очында кояш, яктылык барлыгын-юклыгын да тоймый торган талымсызлык чолганышыннан кайчан да булса котыла алырмы — анысын да уйлап тормый. Тәгәрмәч әйләнә, аның белән Әхмәтсафа, аның кебек язмышлы меңнәр, миллионнар әйләнә...

Уйларын бүлеп, сәркатип хатын — һәрчак пөхтә, эшенә һәм хуҗасына мөкиббән Зифа килеп керде. Кулында бүгенге «Кызыл Татарстан» гәҗите...

Әхмәтсафа тәрәзә артында җай гына аккан тормыш дәрь-

ясыннан шыксыз ярга китереп баскан сыман хис итте үзен, бу халәттән ничек тә чыгарга, җанны урынына утыртырга кирәк иде. Ул, бүген хәл итәргә тиешле эшләрен күңеленнән барлый-барлый, өстәл артына барып утырды.

## X

…Әйе, баш очында болытлар куера, көннәр сәгатьләп түгел, минутлап караңгылана бара, коточкыч көч һәммәсен упкынга сөйри кебек.

Көз көне Татарстанга НКВД наркомы итеп җибәрелгән Михайловның күзенә ак-кара күренми. Моңарчы Тула якларында «халык дошманнары»н фаш итүдә зур өлгерлек күрсәткән бу кыланчык адәм еш кына СССР Эчке эшләр халык комиссары Николай Ежовтан Татарстанда дошман элементларын кыйратырга шәхсән хәер-фатиха алуын кабатларга ярата, әмма Казанда Алемасовтан соң аның кулын кыздырырлык зур кешеләр калмаган, алар инде барысы да төрмәдә, Михайловка кадәр үк Троцкий – милләтчелек төркемнәре башлыклары буларак үз-үзләрен фаш итеп бетергәннәр. Инде калган вак-төяктән зур «элемент»лар ясау кампаниясе колач алып килә. Коткарса, алар гына коткара Михайловның абруен Ежов каршында. Михайловның «бәхетенә», шөкер, 1937 елның июлендә ВКП(б) ҮКның тоткыннарга физик тәэсир итүнең аерым ысулларын кулланырга фәтва бирүе эшне җиңелләштерде. Инде тикшерүчеләр өчен тоткыннарның ни дәрәҗәдә дошман булу-булмавы бөтенләй әһәмияткә ия түгел, бәлки, тикшерүченең тоткыннан күпме вакыт эчендә «кирәкле» мәгълүматларга кул куйдыра алуы беренче планга чыкты. Кем «эш»ен тизрәк төгәлли, ягъни тоткын алдан хәзерләнгән барлык гаепләү кәгазьләренә кул куя, шул мактауга лаек!

Стахановчылык хәрәкәте НКВД подвалларына да үтеп керде, көн саен дошманнарны «сындыру»дагы ысуллар, социалистик ярышны тикшерүгә корылган зур җыелышлар үткәрелеп, «артта сөйрәлүчеләргә» карата рәхимсез шелтәләр белдерелә иде. Әгәр тоткын кулга алынып, «Черек күл»гә китерелгәннең беренче сәгатендә үк алдан әзерләнгән гаепләү кәгазенә кул куймаган икән, ул тикшерүче булдыксызга санала, һаман-һаман «эше» алга бармаса, аның үзен үк, дошман элементы буларак, ватып-имгәтеп камерага кертеп ыргытырга да күп сорамыйлар. Бусы башка тикшерүчеләргә сабак өчен…

«Черек күл»гә эләккән кешеләрнең нинди хәлгә тарыганын Әхмәтсафа якынча чамалый, чөнки Алемасов Михайлов белән еш аралашып тора, тегеләр исә НКВД җәтмәсенә килеп эләккәннәрне ничек итеп изеп-сытып мәгълүматлар алынуы хакында аның алдында тартынмый-нитми сөйләп, көлешеп утыралар. Әхмәтсафаның тәненә суык үрмәли мондый чакта, тә-

мәке төтененә күмелеп айгырлар сыман кешнәшүче бу ике бәндә һич тә кеше затлары түгелдер, ниндидер сәбәп белән Казанда пәйда булган иблис токымнарыдыр кебек иде.

Михайловка корбаннар, бик күп корбаннар кирәк. 1937 елның декабрендә НКВДга егерме ел тула, ә аның әле авыз күтәреп сөйләрлек уңышы юк, һаман шул Алемасов җыеп тотырган милләтчеләр бандасы белән изалана. Аларның инде кешелекләре калмаган, әллә нинди тузга язмаган гаепләүләргә кул куеп бетерделәр, әмма бит аның даны, мәртәбәсе Алемасовка. Ул фаш иткән дошманнар ич алар. Яңа наркомга шымытыр башы, болай барса, Мәскәү арты белән борылачак аңа, өч тиенлек кешегә дә чутламаячак.

...Һәм Михайлов эшкә кереште...

Егерме дүртенче октябрь көнне Мөхәммәтҗанов кулга алынды.

Әлеге хәтәр хәбәр билгеле булгач, Әхмәтсафа үзенең дә көннәренең санаулы калганын чамалады. Тәгәрмәч аның өстенә килә, ул инде аннан котыла алмый, моңарчы беркемне аяп тормаган котсыз тәгәрмәч озакламый аны да сытып-изеп узачак иде. Дәүләтъяровны бу постка беркем белән дә исәпләшми Галим Мөхәммәтҗанов тартып менгезде. Галимнең кулга алынуы аның аркадашларын куркуга төшерсә, аннанерактарак торганнар сөенделәр дә булса кирәк. Яшереп булмый, баш очында болытлар куерганын Галим белеп йөрде, шулай да исән каласына өмете зурдан иде. Үзен саклап калу өчен, икенче секретарь НКВДдан да үткәреп, арадан «дошман» эзләүгә кереште. Аның бу дуамал эше күпләрнең язмышына кырын сукты...

Әхмәтсафа көтеп яши башлады.

Хәлләр торган саен катлаулана бара. Егерме бишенче октябрь көнне Михайлов Кызыл Йолдыз районында, «наркомзем эше» дигән нәмәрсә оештырып, унтугыз кешелек комиссия төзеде. Котлы Бөкәштә эшләп алган кеше буларак, бу «эш»нең дә аңа ачыктан-ачык куркыныч тудыруын яхшы аңлый иде Әхмәтсафа. Заманында, Мөхәммәтҗановка кушылып, кырда калган башак өчен уракчы хатын-кызларны җәберләүне туктатырга, һич тә булмаса, җәза алымнарын йомшартырга кирәклеге турында авыз тутырып сөйләгән бердәнбер райком секретаре иде бит ул... Котлы Бөкәш эше буенча дистәләрчә кеше кулга алынган дигән хәбәрне ишеткәч, күзеннән йокы качты.

Әмма ноябрь ахырларына кадәр аңа тими тордылар. Үзенең вакытлыча гына тынычта калуын ул инде яхшы аңлый иде.

...Ил, яңа конституция кабул ителгәннән соң, беренче сайлауларга әзерләнә.

Өлкә комитетыннан алдан төзеп җибәрелгән исемлекләр

буенча урындагы сайлау округлары кандидатлар «күрсәтә» башладылар. Өлкә югарылыгындагы җитәкчеләр кайсы төбәктән «сайланырга» теләүләрен үзләре хәл итәргә тиеш иделәр. Әхмәтсафа, танышлыкка йөз тота дигән урынсыз шик тумасынга, элек эшләгән Минзәлә һәм Кызыл Йолдыз районнарын түгел, ә үзенә таныш булмаган диярлек Чистай районыннан Югары Советка депутатлыкка кандидат булып теркәлергә карар кылды.

Ноябрь башында «Кызыл Татарстан» газетасы Чистайдагы судноларга ремонт ясау заводы, агач әйберләр эшләү фабрикасы һәм «Красный двигатель» заводы эшчеләре, белгечләре, хезмәт ияләре Милләтләр Советына депутатлыкка кандидат итеп — Сталинның, Союз Советына — Татарстан ХКС рәисе Дәүләтъяровның кандидат итеп күрсәтелүен хәбәр итте. Шул ук округтан РСФСР Милләтләр Советына, Советлар Союзы Герое, академик, данлыклы котыпчы Отто Юльевич Шмидт, Яңа Чишмә районыннан Союз Советына — Татарстан өлкә комитетының беренче секретаре Алемасов, Милләтләр Советына НКВД наркомы Михайлов «күрсәтелде».

...Озак та үтми Казанга, сайлаучылар белән очрашуга, Отто Юльевич Шмидт килеп төште. Шмидт — Советлар Союзы каһарманы исемен йөрткән кешеләрнең беренчеләреннән иде.

1937 ел башында Ленинградтан Владивостокка Төньяк диңгез аша бару юлын тикшерү экспедициясе оештырылды. «Челюскин» бозваткычына таянып оешкан экспедициянең җитәкчесе итеп академик О.Ю. Шмидт билгеләнде. Февраль аенда экспедиция Чукот диңгезендә бозлар арасында кысылып, кораб су төбенә китә. Шмидт кул астындагы йөз дә өч кеше боз өстенә төшеп, ике ай дәвамында яшәү өчен көрәш барды. Арктика ихтыярында калган котыпчыларны очучылар коткарып калмаса, бу хәл ни белән бетәр иде, билгесез. Бәхеткә, алар исән-имин кире өйләренә кайта алдылар, алар — хәзерге көндә совет кешесенең теләсә кайда, теләсә нинди шартларда да табигатьтән өстен чыгуын, теләсә нинди бәлаләрне үтеп, җиңә алуын исбатлаган тере батырлар.

Шушы вакыйга уңаеннан 1934 елның апрелендә Советлар Союзы каһарманы дигән исем булдырылды, һәм менә көзге көннәрнең берсендә шушы каһарманнарның иң атаклысы Шмидт белән Әхмәтсафа кул биреп күреште, берничә көн сөйләшеп, көлешеп йөрү дә насыйп булды.

Кунакның вакыты тар. Казанга килеп төшкән мәлендә үк:

— Һәр минут бүленгән булсын, кешеләр белән очрашыйк, сөйләшик, мине Татарстандагы эшләрнең торышы белән яхшылап таныштырсагыз иде,— дип үтенде.— Депутатлык вазифасы — изге вазифа, киләчәктә минем Татарстанга файдам тия икән, димәк, бу йөрүләр бушка китмәгән, диярбез. Ә

болай исем өчен генә депутат булу ярамый. Халыкны алдау була бит ул,— дип тә өстәде.— Йә, кандидат әфәнденең кереш сүзе шуның белән тәмам, калганын халык алдында сөйләшербез, Аллага тапшырып, эшкә башлыйк.— Шмидт рәхәтләнеп көлеп җибәрде. Мондагы түрәләргә караганда ул үзен күпкә иркен тота, Алемасов белән Михайлов, аңа карата этлек эшләү түгел, үзләре куркудан шыр җибәргәннәр, каһарманга ярарга тырышып, йөгереп кенә йөриләр. Их, үзеңне Шмидт кебек үк бәйсез тота алсаң иде ул! Әхмәтсафаның күңелен җилкендереп шундый уй уйнаклап үтте.

Шмидтның тизрәк халык белән очрашырга дигән теләгенә каршы төшеп булмый инде, бер төбәктән сайланачак депутатлар буларак, Алемасов, Дәүләтъяров, Михайлов, Шмидт, ике машинага утырып, Чистай ягына очрашуларга чыгып киттеләр. Аның янында һәркем үзен иркенрәк хис итә иде, шуңа үзара сөйләшкәндә, бер-берсенә төрттереп «кандидат әфәнде» дип кенә җибәрәләр, соңгы чорда арадан «дошман» эзләү мәшәкате тәмам ялыктырган, талкыган, шулай иркенәя алганнарына Михайловтан кала һәркайсы канәгать, шат иделәр.

Шмидт — чибәр кеше, озын гәүдәсенә караганда, көтелмәгәнчә җитез хәрәкәтле, көрәктәй сакалы түшенә үк төшеп тора, котыпчылар өчен махсус тектерелгән тун кигән, башында алтын кокардалы фуражка.

Әхмәтсафаның өстендә юка пальто, башында яратып кия торган кәпәч, шыксыз ноябрь җиленә исе китмәгән булып кыланса да, суык үзенекен итә, әкренләп эчкә үк үтәргә маташа.

Тун кигән Шмидт ара-тирә шаяртып та ала:

— Син, иптәш Дәүләтъяров, белеп киенгәнсең, машинага җәһәт кенә менеп утырасың, ялт сикереп төшәсең; тун кигәч, мин мәрәләп кенә йөрим менә.

— Митингларда да рәхәт аңа, безнең артта ышыкланып кына тора,— дип сүзгә кушылды Михайлов. Аның өстендә күн тышлы тун, ноябрьнең дымлы суыгын ул үзе дә, янәшәдә кышкы пальто киеп басып торган Алемасов та җиңел кичерәләр иде.— Дәүләтъяров кигән төсле пәлтә миндә дә бар. Кыйммәтле ул, шаярмагыз, хакы түгәрәк кенә, минеке башкарак фасонда, шулай да бәясе ай-һай... Дәүләтъяров начар яши дип булмый.— Михайловның тавышында үчегү сизелсә дә, аңа игътибар итмәскә тырышсалар да, тел төбендә яткан кинаяне яхшы аңладылар.

Әхмәтсафа суыкка да, эссегә дә яшьтән чыныгып үскән кеше, Михайловның үчләшеп маташуын ишетмәгәнгә сабышып, Шмидтның шаяртуына гына шаяру белән җавап кайтарды:

— Өши башласагыз, үземә әйтегез, пәлтәмне биреп торам, бүгенге көнне дә суык дип әйтсәгез инде... Кыш көне чыпчыклар катып үлгәндә дә, яланкул, шушы пәлтә белән йөрим мин.

— Молодец! — Шмидт, елмаеп, Әхмәтсафаның кулын кысты. — Бирешмә! — Нигәдер аны Шмидт якын итеп, җай чыккан саен дустанә сөйләшеп ала, моңа бигрәк тә Михайлов игътибар итә, ачуы килгәнен яшерми, Әхмәтсафаны читкә өстери.

— Кунакны Алемасовтан аерасың, понимаешь, чаманы онытасың, авыл гыйбаты булма инде, канса да канис! Кунак милли кадрларны юри шулай сыный ул, өлгергән кешеләрме болар, шәхесләрме, әллә кибәк башлармы? Ә син, беркатлыланып, Шмидт култык астына киләсең дә керәсең, киләсең дә керәсең. Күз өстендә каш, күт өстендә янбаш... Табылды олы нәчәлник, ачуым бер килмәгәе.

Әхмәтсафа бу бәйләнчек кеше белән сүз көрәштереп тормады, читкә тартылды.

Кунак булып йөрүнең бер читен ягы бар — арадан берсе бераз «төчкертеп» җибәргәч, үзен башкаларга караганда бөегрәк, даһирак хис итә, көйләтә башлый, һәркем аны гына тыңларга, аны гына җөпләп утырырга тиеш дип саный. Югыйсә күренеп тора, өч тиенлек акылы юк, бу бәндәгә хәзер үк җүләрлеккә белешмә тоттырып, дуңгыз көтәргә генә чыгарып җибәрәсе. Әмма андый «бөек» шәп белә, мондый вакытта акылы булганнар, тавыш чыкмасын дип, нәкъ менә аның белән генә булашачаклар, аны гына тыңлап азапланачаклар, аны гына көйләячәкләр, белеп дуамаллана, белеп кыдрачлана, эчмәгән чакта андый бәхеткә тиенә алмый ул.

Чистайда очрашулардан соң кәефләнеп алган Алемасов, Яңа Чишмәгә юлга кузгалганчы, Казанда калган Ширә Хәбипованы таптыра башлады. Әхмәтсафа өч-дүрт сәгать эчендә кызны монда китереп җиткереп булмавын, аларны исә Яңа Чишмәдә ашкынып көтеп торуларын ачыктан-ачык әйтеп салды. Мондый чакта Беренченең көйсезләнүенең урынсыз икәнен дә искәртте. Халык сарык түгел, һәр адымны игътибар белән күзәтеп торалар әнә. Татарлар эчкән кешене өнәмиләр, татарның холык-халәте дә, шәригать тә тыя бу нәмәрсә белән булышуны.

Алемасов, сүз аның өчен нечкә әйбергә — милли гадәт, йолага килеп кагылгач, чигенә башлаган иде, аңа ярдәмгә Михайлов килеп җитте.

— Нәрсә шәлперәйгән тавык сыман аяк астында чуаласың, Дәүләтъяров? Җитмәсә, акыл сатуга керештең. Дәлилләп сөйлә, халыктан оялырлык нинди гамәл кылдык әле без? Причем монда татарлар? Йә, йә, әйтеп бетер, әллә Казанга кайткач, кемгәдер әләк язаргамы исәбең? Александр Михайловичның сүзен аяк астына салырга кем син, понимаешь? — Михайлов та кызмача, ул әтәчләнгәннән-әтәчләнә бара иде. — Беренче, сине үз кешегә санап, Казаннан чыкканнан бирле сыңар үтенеч белән мөрәҗәгать итә, притом, шәхси планда гына түгел бу үтенеч, мәгънәсе бар аның —

безнең янда бер яшь кеше, комсомол әгъзасы кирәклеге көн кебек ачык. А то без монда трибунага килеп чыгабыз дүртәүләп, понимаешь, барыбыз да җитди, барыбыз да түрәләр, халык гадилекне ярата, яшьлек ялкыны иңдererлек кеше юк делегация составында. Татарлар, имеш... әллә кем булганнар! Күрсәтермен мин сиңа татарны! Татарның кем икәнен күрәсең килсә... Хәер, вакыт җитәр, үзең белерсең.

Әхмәтсафаның бирешәсе килмичә, әрепләшә бирде:

— Яшьләр бит Чистайда да, Яңа Чишмәдә дә бетмәгән. Чистайда чыгыш ясаучыларның яртысы диярлек яшьләр иде.

— Урындагылардан туеп беткәннәр инде алар. Нәрсә карышасың, Совнаркомда машина беткәнме, шоферлар юкмы? Хәзер үк Александр Михайловичның күрсәтмәсен үтә! Үзең булдыра алмасаң, минем урынбасарым Шелудченкога хәбәр сал. Василий Иванович кушты, диген, Хәбипованы җир астыннан табып, Яңа Чишмәгә китереп җиткерсен.

Алемасов үпкәләгән кыяфәт белән бер читкә барып баскан иде, Михайловның сүзләреннән иңнәренә канат үскәндәй булды. Михайловны кочаклап, колагына пышылдап алды:

— Кем кулына калдык, Вася, анасын сатыйм...

...Яңа Чишмәдә очрашулар башланырга өлгермәде, Ширә Хәбипова Алемасов янында чытлыкланып басып тора иде инде...

Алемасов шушы хәлләрдән соң Әхмәтсафаны күрмәгән кебек кылана башлады. Казанга кайтырга кузгалыр алдыннан Михайловка берничә мәртәбә ысылдады:

— Кайткач, искә төшерерсең әле, миндә Дәүләтъяров турында материал ята,— диде.

— Мин дә аягөсте йоклап йөрмим, Александр Михайлович,— диде Михайлов һәм, тәкәбберләнеп, ХКС рәисе ягына караш ташлады.— Бездә дә материаллар җыела тора, егетнең күкесе кычкырды инде...— Михайлов, Шмидт белән әңгәмә корып торган Әхмәтсафага астан гына карап, авызын чалшайтты.— Явно корткыч бу, каян килеп эләккән монда, шундый зур постка кем китереп тыккан диген?..

— Мөхәммәтҗанов кадрлары инде. Шуның тегермәненә су коеп йөрүче... Татарлар белән сак эш итәргә кирәклекне аңлагансыңдыр, Василий Иванович?

— Тезгенне йомшартканны көтеп кенә торалар, хәзер холыкларын күрсәтә башлыйлар. Казанга килгәннән бирле, җик күрдем инде мин алардан.

— Аларны даими курку хәлендә тота алсак кына Татреспубликада уңышка ирешеп булачак. Курку хисе генә татарларны асыл инстинктка — үз-үзләрен саклау инстинктына кайтара, шушы хис булганда, без үзебезне тыныч тота алачакбыз. Кеше үз-үзен саклау турында уйлый башладымы, идея, дуслык, намус, вөҗдан дигән төшенчәләрнең поты сукыр бер

тиенгә әйләнә. Курку хисе чигенсә, татар каршылык күрсәтә башлый, рухы көрәш таләп итә аның, холкы шундый бу халыкның, канында борынгыдан сакланып калган кыргый хисләр өскә калкып чыга. Яман нәрсә ул кан уйнавы...

— Менә бит нинди шәп психолог икәнсез, ә Дәүләтъяров Сезне татарны белмәүдә гаепләп маташты.

— Минме татарны белмим?! — Ул үз янына Ширәне чакырды.— Ширә, әйт әле Василий Ивановичка, мин татарны әйбәт беләмме? — Алемасов, кылтаеп, уч төбе белән Ширәнең арт ягына шапылдатты.

Кызның битенә алсулык йөгерде. Шулай да үзен тиз кулга алды:

— Ой, Александр Михайлович, Сез белмәгән нәрсә бар микән дөньяда! — дип, Беренчегә сыенды. Алар күптән түгел генә мунча кереп чыкканнар иде, кызның юеш чәче Алемасовның битенә тиеп китте.

— Александр Михайлович ни-нәрсәләр белә, анысы миңа караңгы, әмма Татреспубликаның беренче чибәре аның кулында,— диде Михайлов, көнләшкән сыманрак.

Алемасовның күңел түреннән икеләнүгә охшаган сәер хис чабып үтте. Ул төгәл генә эләктереп ала алмады — Михайлов кемнең салпы ягына салам кыстырды, аңамы, әллә кыз адресына тәгәрәдеме бу нәзакәтле сүзләр?

Михайлов Алемасовның күңелен кузгаткан икеләнүле уйларны сизми тезә бирде. Беренче дөрес чамалый, бигрәк тә кыз алдында кылчыклана иде НКВД наркомы:

— Шулай инде, Беренчегә — беренче чибәр... Безгә, каткан тезгә, ничәнче сортлылары эләгә торгандыр,— дип уфтанган булды.

Аның кызга нәфесе барлыгын чамалаган Алемасов, эчтән генә: «Ашыкма, Вася, минем кем икәнне белеп бетермисең, кирәк булса, үзеңне дә баш бармак тирәсендә әйләндерергә сәләтле абзаң бу. Инде дә килеп, нәфесеңне кемгә сузарга белмисең икән, үпкәләмә, мөчтиеңне, кисеп алып, кулыңа тоттырырмын. «Черек күл»дә күп уйлап торган булмады, карышудан туктамаган хәшәрәтләрнең кадерле шәрифләрен кесәләренә генә салып чыгара идем!..» Карашын Дәүләтъяров белән әңгәмә корган Шмидт ягына күчерде. «Күңелсез кешеләр болар, эшем ияләре, шушы ике көн эчендә бөтен Татарстанны өч мәртәбә яңабаштан корып чыктылар. Тел — сөяксез, эшләп тә күрсәтсәгез...»

## XI

Җаны урынына утырмый гына бит. Югыйсә шыксыз көннең киләсен белә иде, үзен шуңа хәзерләп тә маташты. Кала, барысы да кала, хыяллар да, шатлык-хәсрәтләр дә, үкенеч-

ләр дә кичәге көндә калалар. Бүгенге башка, бүгеннән ул беркем дә түгел дип әйтерлек, кәнәфидә утырган курчак мисалындагы җан иясе. Тере курчак... Нигә үкенергә? «Инкыйлабка кешеләр түгел, идеягә табынган, аңнары томаланган, күңел күзләре сукыр җан ияләре генә кирәк»,— дип, кем тәкрарлый иде? Мифтах хәлфә сүзләре бу. «Күзегез ачыла башласын әле, үзегезнең нинди хәлдә икәнегезне аңлый башлаган көнне үк сезне берәм-берәм арыслан авызына томырачаклар»,— дип, кем аһ-ух килде? Гомәр абзый бимазаланды, инкыйлабка җанын да, тәнен дә тапшырган меңләгән язмышларның очсыз ахырын алдан күреп ул өзгәләнде.— «Җан белән тән Илаһияткә генә буйсынырга тиеш, илаһи әмерне көтмичә, көн туа алмый. Сүзләр — пүчтәк, Идея — ялган, күзгә тотен җибәрү; яңа дигән һәрнәрсәнең төбендә искеләрнең шагыйранә ялганнары ята. Адәм баласы туганнан алып үлгәнчегә кадәр әкиятләргә ышанып, Саламторхан, Шомбайларга табынып яши. Кешеләр үзләренең, нәселләренең ярлы-фәкыйрьлеге белән масая башладылар. Моннан да көлке ни бар? Башкалар казганып тапканны үзләштерү, җиңел кәсеп, эшләмичә тиз баеп китәсе килүдән дә матур ялган була аламы? Бүгенватканны иртәгә төзәтү, бүген туздырганны иртәгә җыеп алырга азаплану иҗтиһатка саналмый, туганнар. Агач янына агач утыртып ишәя урман, тамырларны яндырып түгел...»

И Мифтах хәлфәм, и Гомәр агаем! Сезкәйләрнең алтын акылларын, нәҗескә батырып, әллә кайчан чүплеккә чыгарып ташладык. Көне килгәч, эзләп карыйбыз да, табып кына булмый. Кая карама чүплек бу илдә. Тау-тау чүплек, дәрьяларга сыймас күз яше. Бу илнең туграсы шул инде. Әхмәтсафа туграны тудыруда үзе катнашты, иң алгы сафта үзе йөрде, инде иблис әмере аның үзенә килеп кагылган икән, идея күлмәгеннән теленеп төшкән тасма аның бугазын буып тын ала алмас хәлгә китергән икән — кемгә рәнҗергә, кемгә үпкәләргә?..

Адарынуларның әҗере тияр көн җитте шул. Саташып аткан таңга алданып, йокыларыннан миллионнар сикереп торды, йоклап калмаганнарына, уянып өлгергәннәренә, Идеянең шәрә ботыннан күз алмый, күлмәк чабуына тотынып бара алуларына и сөенештеләр, и куандылар; юлларында очраган һәммә нәрсәне ватып-туздырып офык ягына чабыштылар. Офык буйлап үрсәләнеп йөргәннәрне берәмләп тә, өерләре белән дә дию авызына ыргыталар әнә, исәннәре кул чәбәкләп тора, озакламый үзләренә дә чират җитәсен уйламыйлармы алар?.. Илаһи әмер дигәне иблис фәрманы гына булган икән бит, ялган таң кабына да сүнә, дөнья төн кармавычында кала икән. Кояшның кайчан чыгасын Ходай үзе генә белә, аның илаһи әмере белән туа яңа көн...

Көннән-көн төшенкелеккә бирелә бара ул.

Ноябрьнең соңгы көннәрендә республика газеталарында

аның исем-фамилиясе күренми башлады. Бу кисәтү генә түгел, аны ачыктан-ачык сәяси мәйданнан читкә тибәрү, язмышының хәл ителгәнлеген искәртү иде. Кем тыя матбугатны хөкүмәт җитәкчесенең абруена каршы эшләргә? Бу хакта газета мөхәррирләре үзләре әйтмәячәк, шылтыратып сорау түбәнчелек кенә түгел, күрә торып башны утка илтеп тыгу. Көне-сәгате белән кирәкле оешмага хәбәр китәчәк, аны кулга алуны тизләтергә бер сәбәп кенә булачак мондый адым.

Кемнәр аңа каршы, кемнәр аны түбәнсетергә омтыла, кемнәр әле үзе пост биләгән чакта ук аны ил күзеннән яшерергә тырыша? Алемасов, Михайлов исемнәре гәзит битләреннән төшми дә әнә. Алда үзен ни көткәнен уйласа, йөрәк кымырҗып куя. Инде бу хакта җай чыккан саен, уратып-чуратып дигәндәй, хатыны Рабигага да сиздереп ала.

Беркөнне әтиләренең муенына асылынган Марат белән Марлесның чыр-чуыннан арып, аларны тыярга маташкан Рәбушын да көчле куллары белән эләктереп үз күкрәгенә кысты һәм сак кына пышылдады:

— Тимә... Уйнасыннар... Бу минутларны сагынырбыз әле...

— Син, әллә нәрсә, Сафа, йөрәккә шом салып сөйлисең бу араларда,— диде Рабига, шул минутта күзеннән яшь атылып чыкты.

Сәрсән Маратка шул җитә калды, такмаклый башлады: «Елак-мылак, ертык колак».

Үз уены белән мәшгуль Марлес, тик торганда абыйсы аны үрти дип, кычкырып елый башлады.

— Йә, йә, булды,— диде битәрли төшеп Әхмәтсафа.— Барыгыз, әбиегез янына керегез, йокларга вакыт инде.

Балаларны, көйләп-чөйләп дигәндәй, йокы бүлмәсенә кертеп җибәргәч, Әхмәтсафа, янә Рабиганы кочагына алып, хатынының күзләренә карады:

— Беләсеңме, Рәбуш, без бик тә, бик тә катлаулы чорда яшибез. Кемнең кем икәнен белгән юк, үзебезне иртәгә ни көтәсен дә белмибез. Сөйләшеп, аңлашып кую кирәк. Минем белән алай-болай булса...

Рабига, куркынып, кайнар учы белән иренең иреннәрен япты.

— Куй әле, Сафа, куркытма мине. Болай да яшәүнең яме качты. Эштә бер-беребезгә күтәрелеп сүз әйтергә куркабыз. Нинди ил бу, нинди чор бу?..

— Мин икебез өчен дә мөһим вакытта син куркып, каушап калмасын өчен тырышам. Уен түгел, балалар язмышы беренче урынга чыга мондый чакта. Әгәр каушап, коелып төшсәң, бар көчеңне туплап, үзеңне җыеп тота алмасаң, нишләргә?..

— Мин барысын да аңлыйм... Әмма ни өчен сиңа кыегалар? Синең нинди гөнаһың бар? Юк бит, эш, эш дип вакытыннан алда картаеп барасың, нинди эшкә алынсаң, шул ку-

лыңнан килә, синдәй кадрларны саклап, җайлап эшләтү ягын гына карарга кирәк бит акылы булган җитәкчеләргә.

— Минем бар гаебем шул инде — эшкә артык бирелү, эш күрсәтергә сәләтле булу. Ә бу нәрсә гафу ителми икән өстәгеләр тарафыннан. Шуышып, тәкмәрләп йөрүчеләр заманы килде. Башны югары тотып, җиргә нык басып яшәргә азапланучыларны тиз авызлыклыйлар хәзер. Шуңа алдан ук әйтеп куясым килә... Алай-болай булса-а ...— дип кабатлады сузып Әхмәтсафа.— Мине эзләп «Черек күлгә» аяк та басма, аңладыңмы? — Аның тавышы калтыранып алды, әмма таләпчән яңгыравын югалтмады.

Рабига тавышсыз гына елый иде. Хатынының калтыранган гәүдәсен кайнар кочагыннан аермый, Әхмәтсафа дәвам итте.

— Бел, анда эләккән кешене болай гына, тиз генә азат итмиләр... Ялынып йөрмә, диюем. Үзеңнең иминлегең өчен, балалар хакына эшлә син моны. Әле әни бар янында, Ширазга сыен, мөмкин булса...

— Шираз әле яңа тормыш корып җибәреп маташа. Үзе эшкә керешеп килә, хатынын урнаштырасы бар.

Шираз, Мәскәүдә укуын төгәлләгәч, театрга режиссер булып кайткан иде. Әмма исемле бик чибәр яһүд кызын эләктереп, өйләнеп тә куйган һәм алар, кунакханәдән бер бүлмә алып, шунда гаилә корып яшәп яталар иде.

— Аңлыйм, мөмкин кадәр Шираздан ерак булырга, аны сакларга кирәк. Аның киләчәге зур, ныгыса, Марат белән Марлесны ярдәменнән ташламас. Аннан Җиһан да бар бит...

— Җиһанга ышаныч азрак шул, бәби үстерә, ир дигәне ике хатын арасында бәргәләнгән мәхлук булып чыкты. Һич кайсы якка булырга белми.

— Җиһан хисле хатын, кайнарланып, дуамалланып йөрсә дә, туганлык җебен өзә күрмә, диюем.

— Анысы булмас инде. Бертуган апам бит ул.

— Кызганыч, барып егылып, киңәш сорар кешең юк чамасында. Минекеләр — ерак. Каргалыда хәзер Әхмәтхан гына ныклы тормыш алып бара. Гомәрхан узган ел трактор астында калып имгәнгән, озак ятты больницада, мин, тинтәкләнеп, аның хәлен белергә дә кайта алмадым... Туган дигәндә ни сан?

— Эш дисең бит... Инде Марат туганнан бирле булганыбыз юк авылда.— Рабига яшь аралаш елмайды.— Хәтереңдәме, Каргалыга кайткач, Маратны юрганга төреп сиңа тоттырган идем, бераз карап тор, янәсе. Бала чүпрәкләрен чайкарга дип, үзем Сакмарга төшеп киттем. Кайтып керсәм, син дөньяңны онытып курс эше язып утырасың, ә Мараттан җилләр искән, уңга карыйм, сулга карыйм, кызыл юрганга төргән төенчегем юк кына бит. Мин дулыйм, еламсырап синнән бала таптырам, син исәнгерәп тик карап торасың, коелып төштең, бала турында бөтенләй оныткансың.

— Эшкә мавыгып, син әйткәнне җүнләп тыңламаганмын инде мин, Рәбуш.

— Шулай шул. Бер эшкә тотынсаң, дөньяңны онытасың. Гомәрхан абзыйның кызы Фәүзия ишегалдына алып чыгып китмәгәнме дип, ихаталарны урап чыктым, бичара гөнаһсыз сабыйдан Маратны сораштырып маташтым бугай әле. Анысы кычкырып елый башлады. Тагын өйгә кердем, үзем үкереп елыйм.

— Еларга сиңа куш инде.

— Көлке хәл түгел бит. Шулчак сандык арасында күзгә кызыл нәмәрсә чалынды. Уктай атылдым шунда, тартып чыгарсам — Маратым! Сандык арасына төшеп киткән икән балакаем. Тагын бераз тапмый йөрсәм, шунда кысылып, җан тәслим кыласы булган. Һи, сез ирләргә ышансаң...

...Икенче көнгә эшкә килсә, аны аптыраган йөзле сәркатип хатын каршы алды. ХКС рәисе ишектән күренүгә, урыныннан сикереп торды, сәркатипнең йөзе кызарган, каушаудан исәнлекне дә җүнләп ала алмый тора.

— Нәрсә булды, Зифа? — диде Әхмәтсафа, аның телгә килүен көтмичә.

— Телефонны өзеп куйганнар... Дежур телефонистка әйткән идем, бер сүз дәшми...— Сәркатип каушавыннан кулындагы каләмен идәнгә төшереп җибәрде.— Көн дәвамында эш урынында булсын диделәр сезгә, Сафа Мостафавич.

«Кем кушты?» — дип сорамакчы иде, мәгънәсез икәнен чамалап, дәшми торды. Димәк, аңа да чират җитте...

Кабинет хуҗасы тәненә йөгергән калтырауны сиздермәскә тырышты.

— Аңлашылды,— диде. Әмма тавышын көр итәргә тырышса да, саңгырау чыкты.— Кая, кичә әзерләгән докладны басып бетерденме? Әзер битләрен миңа кертеп бир әле, караштырырга кирәк.

Әхмәтсафа исәңгерәгән халәттә бүлмәсенә үтте, йөрәк януын басарга теләп, графиннан су салып эчте, киемен салып, элгечкә элеп куйды һәм бүлмәгә ничектер сәер караш ташлап алганнан соң, арыган адымнар белән тәрәзә янына килеп басты...

Сәркатип кәгазьләрне өстәлгә куеп чыгып киткәндә, Әхмәтсафа һаман тәрәзә янында, карлы җил бөтерелгән Казансу елгасына карап тора иде...

Берничә минуттан сәркатип янә күренде, өстәлгә «Кызыл Татарстан» газетасының яңа санын китереп салды. Тавышында нindидер өмет чаткылары пәйда булган иде аның.

— Чистайдан хәбәр бар, күз йөртеп чыгыгыз! — диде ул, тавышын күтәрмичә генә.

Әхмәтсафа өстәл янына килде. Аягөсте баскан килеш

кенә газетага күз йөртеп чыкты. Беренче битнең уң почмагында үткән көнне, ягъни егерме тугызынчы ноябрьдә Чистай районының Вахитов исемендәге һәм «Чулпан» колхозларының берләштерелгән җыелышында Галәветдинов дигән колхозчының чыгыш ясап, Дәүләтъяров иптәшнең Союз Советына кандидат итеп күрсәтелүен чын күңелдән яклавын хәбәр иткән кечкенә хәбәр басылган иде...

Шушы хәбәрдән соң Татарстан газетларында Дәүләтъяров фамилиясенең озак еллар телгә алынмаячагын ул белми иде әле, ләкин күңеле сизә — ул инде бүген, гадәтенчә, өйгә кайтып кермәячәк, малайлары белән әвәрә килеп уйнамаячак, Рабиганың тиргәвеннән тәм табып, аны кайнар кочагына алмаячак, юатмаячак, иркәләмәячәк. Ул башка яссылыкка күчте, бүген нидер булачак һәм аның булуы котылгысыз иде... Аның күзләренә яшь тулышты, йөрәген нидер чәнчеп алгандай булды. Ирексездән телефон трубкасына үрелде, аннан исенә килеп, кулын тартып алды һәм өстәл өстендәге кәгазьләргә карап тын калды... Кинәт, нидер исенә төшкән кеше сыман, каударланып өстәл өстенә таралган чыгышын җыйнады да, папкага тутырып, ныклап бәйләп куйды һәм сәркатибенә эндәште. Ниндидер өмет уянган шикелле, йөгерә-атлый Зифа керде.

— Бу папканы Алемасовның кабул итү бүлмәсенә илтеп куй... — диде бүлмә хуҗасы, битараф тавыш белән. — Мөмкин булса, бүгенге хәлләрне безнекеләргә хәбәр ит, яме. — Зифаның аптыраулы карашын тотып, кызганыч елмайды. — Бүген миңа башка җирдә төн үткәрергә туры килер шикелле тоела...

## XII

Алемасов Шмидтны Мәскәүгә озатканнан соң авырыбрак йөргән иде. Хәле юк, шуңа кәефе дә керделе-чыктылы булды. Бүгенге иртәдә генә бераз җан керде аңа. Үзен Казан ханы итеп тоя алуына һаман гаҗәпләнеп бетә алмый утыра әле. Бу хыялга ирек куйсаң, билләһи, тфү, тфү, берәр ләгыйнь сизә күрмәсен, Иван Грозный булып, Мәскәү тәхетенә үк чумасы килер. Казан минем кулда, мин — терелеп, төрбәсеннән күтәрелгән Иван Грозный, аяк астында татар ирләре аунап ята, кочакта татар кызы! Ул монда хуҗа, аңа беркем кысылмый, беркем каршы төшә алмый, ни теләсә, шуны эшли, билгеле, Мәскәү белән киңәшкән булып инде. Башың ике булса, шушы җәннәт бакчасына риза булмыйча, Мәскәүгә үрелеп кара син! Хәер, ике түгел, баш шәрифләрең унау булса да, Мәскәүгә буе җитми аның, әй бу хыял киртәсенә кунаклаган акылсыз уйларны! Ирек бирсәң, дөньясын аяк астына китереп салырлар, валлаһи.

Шулчак ишек ачылып китте, Михайловны күреп, Алемасов урыныннан сикереп тора язды.

Иртүк рөхсәтсез диярлек кабинетына килеп керүен өнәмичә, астан гына НКВД наркомына карап алды:

— Таңнан йөрмәсәң... — диде ул, Михайловның вәкарьлеген сындырырга теләгәндәй. «Тирәндә моның ише «вәзирләр» кайнашканда, булырсың Иван Грозный!» — дип эченнән генә сүгенеп тә алды.

— Төне буе йоклап булмады, — диде Михайлов, карлыккан тавыш белән һәм, әйткәнне дә көтеп тормыйча, Беренче каршындагы йомшак кәнәфигә ишелеп төште. — Усмановны «эш»кә чакырган идем, төне буе киреләнеп, җәдәлләшеп чыкты. Куллар калмады. — Ул, кул сыртын угалап, сызланган тавыш белән өстәп куйды. — Ярдым кабахәтне.

— Ярып кына игә килә торган кешеләр булса алар... Махсус алымнар кирәк. Үземнең дә бер барып чыгасым бар әле ул тирәгә. Куллар кычыта башлады.

Михайлов, кабинет хуҗасының күңелен күрергә теләп, куштанланган булды:

— Эшең күп бит, Александр Михайлович. Энергияңне Хәбипова алып бетерә.

Алемасовка шаяру ошады.

— Куй инде, Вася! — Наркомга болай сирәк эндәшә ул. Димәк, ике арада тулысынча аңлашу барлыкка килде. — Кызның нәфсесе зурдан да бит, көне буе эштән бушап булмый, аның куенына ауганда, җеп өзәр хәл калмаган була. Ярый инде, бөтенләй үк зарланырлык итмим үзен, большевикларча гайрәт күрсәтеп алам... Айгыр, ди бит, юкка түгелдер инде.

Көлешеп алдылар. Михайлов графиннан стаканга су тутырып салды, кулына тоткан килеш, бераз уйланып торганнан соң, һәр сүзен үлчәгәндәй әйтеп куйды:

— Дәүләтъяровның дөнья белән элемтәсе бетте бүгеннән, телефонын өзеп куярга куштым. Материаллар җитәрлек тупланды, алга табан да калдырып булмый.

Алемасов чыраен сытты. Кабих, минем белән сөйләшеп торасы килмәгән, хәзер тавыш күтәреп кара инде. Интрига корырга азаплана, тәре баганасы. Шулай да күңелендәгесен сиздермичә, мыгырданып алды:

— Тәки киләсе елга халык хуҗалыгы үсеше перспективалары турындагы докладын әзерләп тапшырмый, корткыч. Ике кулсыз утырам, әллә соң уникенче декабрь — Югары Советка сайлаулар көненә кадәр түзикме?

— Сез нәрсә, Александр Михайлович! — Михайлов кабынып китте. – Бер минут чигерергә ярамый. Шулай булмаса таң тишегеннән килеп керер идеммени! Инде эш шулай икән, аңа бер көн бирәбез. Белүемчә, доклад, нигездә, әзер дип, өченче көн үк информация ясаган иде.

— Белмәгәнең юк синең, каһәр.

— Вазифа таләп иткән кадәр генә, Александр Михайлович.— Михайлов кәнәфигә утырган килеш киерелеп-сузылды.— Үтә гомер, шушы пычрак арасында болганып, бер рәхмәт ишетмичә...— Ул сынаулы карашын Алемасовка төбәде.

— Ишетерсең, Вася, ишетерсең. Партия һәрнәрсәне исәптә тота. Татарстан сиңа рәхмәтсез булмас дип уйлыйм. Син — минем өчен иң кыйммәтле кадр һәм мин моны Мәскәүгә һәрдаим җиткереп торам.— Аннан гадәти нәрсә хакында сорагандай,— Дәүләтъяров эшен кем алып барачак? — диде.

— Үзем контрольдә тотам. Шелудченко белән Крохичевка куштым, алып килгән шәпкә каезласыннар как следует, аннан «эш»кә кертеп җибәрсеннәр. Шулай боердым.

— Шелудченко ничек соң? Казанга ияләнәме?

— Матвей Ивановичны Мәскәү аша үзем соратып алдым бит. Аның белән эшләп була! Яра гына кулына килеп эләккән контрларны. Шуның өчен туган кеше ул.

— Анысы ярый. Миндә Дәүләтъяровка кагылышлы берничә документ бар; теге чакта да әйткән идем, алып кит әле шуларны.— Алемасов, өстәл өстендәге искерәк папкадан кәгазьләр чыгарып, Михайловка сузды.— Яңалык юк югын, шулай да кирәк булуы бар.

Михайлов артык исе китмәгән кыяфәт белән кәгазьләрне караштырып алды.

— Шәмтив... Кәрим Хәрәмуллин... Берсе — аноним, Татгосиздатта кыланганнары турында, монысы бигрәк әһәмиятле күренә. Өчесе өч төрле бәндә, төрле тармакта эшлиләр, һәркайсы йөрәкләрендә Дәүләтъяровка үч салып йөрткәннәр. Кызык бит, ә?

— Татарлар аягөсте йоклап йөрмиләр бу мәсьәләдә. Берсен аз гына мактап, үсендереп җибәрсәң, икенче көнне өстәлеңдә ун жалоба ятачагын көт тә тор. Үчле, көнчел халык, алар белән зур эшкә алынма, бер-берсен чагып, сатып башларны әйләндереп бетерәчәкләр. Менә шундый төбәктә эшлибез инде, Вася. Партия юкка гына безне монда җибәрмәде. Кисловодск, Ростов, Воронеждагы хәлләр Татреспубликадагы хәлләр белән чагыштырганда чепуха ул. Мыжлап тора монда «халык дошманнары». Дәүләтъяровка материаллар нигезлеме? — Михайловның йөзендә ачулану галәмәтләре чыгуын күреп, Алемасов аны тынычландырырга ашыкты.— Йә, йә, сөмсерең коелмасын, вчүтеки минем бу эштә тәҗрибә бар бит. Милләтчелек карашын алга сөрүче корткычларның ни-нәрсәгә сәләтле икәнен беләм. Изә торасың, сытып, канын сыгып бетерәсең, инде кәгазьләренә кул куя, тетмәсен тетеп, аңсыз хәлдә камерага илтеп болгыйлар; бетте, яңадан телен әйләндереп сүз әйтмәс дип уйлыйсың;

икенче сорау алуга, хәл кергән була хәшәрәткә. Тагын карыша, элек әйткәннәреннән тана башлый, тагын нервыда уйный, фахиш.

— Ишеткәнең бармы, бер Казан шагыйре: «Казан — фахишләр шәһәре»,— дип язган, имеш. Икенчесе: «Ни сәбәптер, тәнгә — мунча, җанга юк»,— дип әйтеп үлгән.

— Күренеп тора, татар язучылары үзеңә азлап-азлап дәрес бирәләр икән. Ну моның икенчесе уңышлы пример түгел, большевистик рухка туры килми. Син аларны азрак тыңла, күбрәк үзеңнең алымнарыңны чарла. Алар, инде бетте дигәч, яңадан сикереп торалар.

— Усманов шулай җәфалый бит инде мине. Кабих, тагын ни генә кыландырырга? Аптыраш.

— Беләм, күпме ярдым мин аны. Каты чикләвек. Усмановның телен чишмәсәң, эшең бик тонык күренәчәк.

Михайлов кергәч тә өстәл өстенә ташлаган папкасыннан кәгазьләр тартып чыгарды.

— Дәүләтъяров эше шушында, Александр Михайлович. Күз төшерсәгез иде. Ул корткычны болай да озак асрадык Совнаркомда…

Алемасов ашыкмый гына кәгазьләрне укый башлады. Укыганда «тәк», «тәк» дип куюы, аның Михайлов эшеннән канәгать булуын күрсәтә иде.

Беренче эш итеп, элекке халык комиссарлары рәисе Абрамов Кыям Әлимбәковичтан әле егерме өченче-егерме сигезенче сентябрьләрдә алынган сорау алу беркетмәсен тартып чыгарды.

Бу папкага буш кәгазьләр салып йөртми НКВД наркомы. Күңеле булды, димәк, Михайлов йокламаса йокламый, әмма теләгәнен йолкып ала белә, профессиональ чекист шулай булырга тиеш тә дип уйлап, канәгать төстә тамак кырды Беренче.

— Йә, укып карыйк, чулак Абрамовниләр сайрады икән?..

Михайлов үтә хәлсез кыяфәттә кулын селкеп алды да, кәнәфигә чума төшеп, күзләрен йомды. «Мин җаннарыннан суырып чыгардым әлеге күрсәтмәләрне, моның нинди авыр эш икәнен үзем генә беләм»,— дигән мәгънәдә иде бу кылануы.

Кыям Абрамов — шахтер, шунда бер кулсыз калган. Үзе белән бергә эшләмәсә дә, Абрамовның булдыклы җитәкче икәнен ишетеп белә иде Алемасов. Берничә көн дәвамында сорауны үзе алды аннан, телен чиштералмый изаланып бетте, исән калган кулын каергалап, ахыр чиктә, сындырып чыгаруын да онытмый. Киребеткән нәрсә булды Абрамов, Алемасовның йөзенә төкергән бердәнбер хәшәрәт ул. Шуңа иң беренче Михайлов эшкә керешү белән, аңа Абрамов белән «шөгыльләнергә» киңәш биргән иде.

Абрамовның акылы үзендә икән әле. Карт төлке, һаман

башкаларны саклап калырга азаплана, Дәүләтъяров хакында бернинди мәгълүмат кысып чыгара алмаган Михайлов, әмма террористик оешмаларның совет хакимиятенә нинди куркыныч тудыруын ачып салган күрсәтмәләр бирә, ягъни аның күрсәтмәләре сак астындагы милләтчеләрне, троцкийчыларны гаепләү эшен «төпле» нигезгә корырга ярдәм итәчәкләр. Ә Дәүләтъяров «корткыч» буларак шушы «мәктәп»-не үткән бәндә. Михайлов эшне дөрес оештыра, молодец! Бу күрсәтмәләр өчен дә Михайловка, ким дигәндә, ике-өч көн «тырышырга» кирәк булганын яхшы аңлый ул.

Ашыкмый гына беркетмәне укый башлады. Күз алдында тикшерүче белән Абрамов арасында барган «шома» әңгәмә шәйләнә:

— Сез әле контрреволюцион оешмаларның террористик ниятләре турында мәгълүматлар бирмәдегез.

— Контрреволюцион уңтроцкийчы, пантюркистик оешма үзенең ахыргы максаты итеп, совет властен бәреп төшерү һәм капитализмны кире торгызуны күздә тотты. Бу максатны тизрәк тормышка ашыру ниятеннән без ВКП(б) һәм совет хөкүмәте җитәкчелегенә, беренче чиратта Сталинга каршы юнәлтелгән террористик актлар куллану уенда идек.

— Сөйләгез, сөйлә, мин тыңлыйм...

— Бу күрсәтмә хакында миңа турыдан-туры Габидуллин 1934 елда Мәскәүдәге эш кабинетындагы очрашуларның берсендә әйтте.

— Анысы кем була?

— Габидуллин Хаҗи Заһидулла улы, 1870 елда туган, егерме дүртенче-егерме җиденче елларда ТАССР ХКС рәисе булып эшләде, аннан Мәскәүдә, пантюркизм һәм панисламизм тарихы турында «хезмәт»ләр язды. Ул миңа: Сталинны үтерү вакыйгаларны без теләгән юнәлештә тизрәк хәрәкәтләндерергә мөмкинлек бирәчәк, чөнки Сталинны үтергәч тә илдә паника башланачак, юлбашчыга үч саклап йөрүче партиядәге һәм партиясез элементларның куллары чишеләчәк,— диде.

1934 елда Разумов белән сөйләшкәндә, ул да уңтроцкийчы контрреволюцион оешманың Сталинны һәм аның аппаратында эшләүчеләрне үтерүне максат итеп куюын әйткән иде. Бу юнәлештә инде эшнең барганлыгын, кайбер төбәкләрдә террористик төркемнәрнең оешуын һәм аларның форсат кына көтеп торуларын әйтте. Террористик ниятне аеруча алга сөрүчеләр: Мәһдиев Каюм — финанс эшләре халык комиссары, Ганиев Гали Ганиевич — 1928–1930 елларда ТАССРның ХКС рәисе булып эшләде, 1934–1937 елларда җиңел, соңрак җирле сәнәгать наркомы булды, Рәхмәтуллин Фазыл — ВКП(б) өлкә комитетының агитпром бүлеге мөдире һәм Касыймов Газим — Казан педагогия институты директоры.

Тикшерүче бу көнне Абрамовтан башка күрсәтмәләр сы-

гып чыгара алмаган, ахры. Беркетмә шуның белән тәмам. Иң мөһиме, уй-ниятләре ачык күрсәтелгән иде контрларның.

Алемасов, кулындагы кәгазьләрне әйләндереп-барлап карады да, ризасыз тавыш белән:

— Боларның берсендә дә гаепләнүчеләрнең имзалары юк бит. Ялган димәсләрме? — диде.

— Ялган — һөнәр ул! — диде Михайлов, тәмәке кабызып, тирән итеп төтен суырып алгач.— Безнең эштә,— дип тә өстәде.— Александр Михайлович, үзең беләсең, һәр кәгазьгә кул куегыз әле дип, ул хәшәрәтләр артыннан йөгереп йөри башласаң, ни була? Кирәкле показанияләргә кул куйдыртылган, шунысы артыгы белән җиткән!

Алемасов ирен чите белән генә елмаеп куйды һәм укуын дәвам итте. Бусы инде егерме җиденче ноябрьдә, дәүләт куркынычсызлыгы начальнигы ярдәмчесе, дәүләт куркынычсызлыгы лейтенанты Моргалин өлкә комитетында Культпроп җитәкчесе булып эшләгән, инде кулга алынган Чукальский Петр Максимович белән «сөйләшкән».

— Шуны гына беләм, мин ВКП(б) өлкә комитетында культпропта эшләгәндә, Дәүләтъяров хәзер инде кулга алынган кешеләр белән берлектә (Хәйретдинов, Абашев, Григорьев һәм башка Татарстан китап нәшрияты хезмәткәрләре) марксизм-ленинизм классиклары әсәрләрен тәрҗемә итү эшенә тартылды. Бу участокта җибәрелгән корткычларча браклар Хәйретдинов, Григорьев һәм Касыймовлар эше генә түгел, бәлки, анда Дәүләтъяровның да өлеше бар.

Аның уңтроцкийчы контрреволюционерлар белән элемтәдә тору-тормавын мин белмим, әмма бер фактны искәртәсе килә, ул — Исхак Рәхмәтуллин һәм Бари Абдуллинның канатына сыенып яшәде…

…Сыек, күрсәтмәләр бик сыек, әллә соң бу Михайлов эшне бөтенләй үз агымына куйганмы? Гел шуныңише вак-төяк булырмы икән дип, шикләнебрәк Алемасов өченче беркетмәне кулына алды, йөзенә сөенеч нурлары җәелде, бусы инде асыл кош — Татарстан өлкә комитетының элекке беренче секретаре Лепадан алынган күрсәтмәләр иде. Лепаны фаш итү Алемасовның Казан биографиясендә олы казаныш иде. Альфред Карлович Лепа — 1917 елдан 1937 елга кадәр, ягъни кулга алынганчы, ВКП(б) әгъзасы, советка каршы эшчәнлеге өчен партиядән чыгарылган. Кулга алынганчы, ВКП(б) ӨК беренче секретаре булып эшләгән. Дүртенче бүлекнең начальник урынбасары өлкән лейтенант Крохичев сорау алган беркетмәләр Дәүләтъяров эшенә шактый «ачыклык» кертә иде инде.

— Дәүләтъяров турында нәрсә беләсез, сөйләгез.

— Утыз бишенче елда Кызыл Йолдыз районында секретарь урынбасары булып эшләде, партия документларын тикшергәндә, партия оешмаларын алдашуга этәрде, шуның белән

ВКП(б) ҮК директиваларын бюрократик формаль үтәүгә юл ачты. Яхшы хәтерлим, Кызыл Йолдыз партия оешмасында ҮК күрсәтмәләрен өйрәнмәделәр, партия сафларын чистартканда, сыйнфый-чит элементларны фиркадә калдыруга юл куелды.

— ВКП(б) райкомының беренче секретаре кайда иде соң?

— Кызыл Йолдыз райкомының беренче секретареның фамилиясе исемнән чыкты, ул шуннан соң МТС политбүлеге начальнигы булып Норлат районында эшләде. Дәүләтъяров белән берлектә районда ачылган тәртипсезлекләр өчен гаепләнде, Дәүләтъяров белән берлектә эшеннән алынды.

— Кызыл Йолдыздан эшеннән алынганнан соң, Дәүләтъяров кайда, нинди вазифа башкарырга җибәрелде?

— Кызыл Йолдыздан секретарь урынбасары эшеннән алынгач, ул Татгосиздатка эшкә билгеләнде, бераз вакыттан соң ВКП(б) ӨК икенче секретаре Мөхәммәтҗановның үтенечен һәм рекомендациясен искә алып, китап нәшриятының редакторы итеп куелды. Шушында әйтер идем, Дәүләтъяров Мөхәммәтҗанов белән, гомумән, якын мөнәсәбәттә тордылар, аларны антисоветчыл милләтчелек берләштерде, моны миңа Мөхәммәтҗанов үзе әйтте.

— Дәүләтъяров хакында сез тагын нәрсә әйтә аласыз?

— Үзенең антисоветчыл эшчәнлеген яшереп, Дәүләтъяров барлык чыгышларында да озак вакыт дәвамында бары тик бер үк кешеләрне генә тәнкыйть итте. Бу кешеләрнең китап нәшриятындагы корткычлык эшләре турында фактлар күптән ачылган, билгеле иде инде. Китап нәшриятында үзе килгәч эшләнелгән корткычлыклар турында ул ләм-мим эндәшмәде. Шулай ук Дәүләтъяровның Мәскәүдә Кызыл профессорлар институтында белем алгандагы тәртибен дә тикшерәсе иде.

Алемасов уйга калды. Белгәненчә, Әхмәтсафа Дәүләтъяров Мәскәүдә укымаган, Казанда ТКУны тәмамлый. Аспирантураны да Казанда үтә. Кайчан укыган соң ул Мәскәүдә?

— Бу Дәүләтъяров Мәскәүдә белем эстәп йөргәнмени соң?.. Лепа сөйли моны,— дип, йокымсырап утырган Михайловка эндәште.

— Юк ла инде, Лепа саташа, ныграк тондырганнардыр башына.— Михайлов ихылдап алды.

* * *

Шушы ук эшкә атаклы язучы Габит Низам күрсәтмәләре дә теркәлгән.

Алемасов бу кешене белә, түгәрәк гәүдәле, нык бәдәнле, аны кыйнарга, бигрәк тә типкәләргә рәхәт иде. Ай-яй, аның белән шактый җәфа чикте ул, шулай да суккалый-каккалый торгач, егетнең теле «чишелде», күрсәтмәләрне шактый сыгып алдылар аннан. Менә бит, әгәр дәүләт куркынычсызлы-

гы сержанты Гатин тотынмаса, Габит Низам бу кадәр «сөйләп» ташлар идеме. Беркетмәләрдә үзенең кулы юк югын, әмма Гатин фамилиясе бар икән, шикләнмичә әйтергә була, Габит Низам бу сүзләрне кире какмаячак. Сорау егерме сигезенче ноябрьдә алынган иде.

— Дәүләтъяровның контрреволюцион һәм корткычлык эшчәнлеге хакында Сез нәрсә беләсез? — дип сорый Гатин.

Беркетмәне читкә алып томырасы килде Алемасовның. Эх-ма, шайтан алгыры, шушы бәндәләргә баш хәрефтән Сез дип язып, протокол сырлап утыр инде. Совет иле шул бу, кеше белән исәпләшәләр, кая инде итагатьлелек кайгысы «эш» барышында, артлары бөрешкән тавык бит алар, җыен проститутка! Ә менә язганда истә тотарга туры килә. Тәртип есть тәртип, НКВД сержанты, Алемасовның иң яраткан чекисты Сөнгатулла Корбанов әйтмешли, кәгазь чыдый инде, кая барасың. Ярый, Гатин нәрсәләр «тезде» микән?..

— Дәүләтъяровны мин 1933 елдан беләм,— дип җаваплаган Габит Низам.— Шул елда элекке ВКП(б) ӨК секретаре, хәзер инде фаш ителгән «халык дошманы». Бари Абдуллин Казан шәһәрендә яшәүче һәм культура фронтында эшләүче татарлар гына чакырылган партактив җыйды. Көн тәртибендә контрреволюцион буржуаз милләтчелеккә каршы көрәш мәсьәләсе куелган иде. Кайбер чыгышларда культура фронтына кереп оялаган буржуаз милләтчеләрнең контрреволюцион эшчәнлекләре хакында искитмәле фактлар яңгыраса да, Дәүләтъяров үз чыгышында бу фактларны күмеп калдырырга тырышты, аның чыгышының духыннан күренгәнчә, күрсәтелгән фактларда аның да катнашы барлыгы ярылып ята иде һәм либераль тешсезлеге ягыннан Абдуллин белән Әхмәровның декларатив лыгырдауларыннан берни белән дә аерылмады. Чынлыкта Абдуллин, Әхмәров һәм Дәүләтъяровлар үз чыгышларында партактивның башын бутап бетерделәр, аларның Газыйм Касыймов һәм башкаларның икейөзле бердәм хорына кушылулары көн кебек ачык иде. Партактивның барлык утырышында да Дәүләтъяровның Абдуллин белән Әхмәровка нык якынлыгы күзгә ташланып торды. Хәтта утырышларга да бергә керделәр, бергә чыгып киттеләр.

Соңрак (1934 елдамы, әллә 1935 тә) Дәүләтъяров һәм Әхмәров Ленин һәм Сталин әсәрләрен тәрҗемә итү комиссиясенә килеп керделәр, бу комиссиягә 1935 елга кадәр Абдуллин, аннан соң Әхмәров җитәкчелек итте. Шушы вакыйгалардан бирле Дәүләтъяровның фаш ителгән «халык дошманнары» Исхак Рәхмәтуллин, Әтнәгулов, Хәйретдинов, Ризванов һәм башкалар белән бәйләнештә икәнен күреп йөрдем. Башында Дәүләтъяров торган әлеге комиссия Абдуллин, Рәхмәтуллин, Ризванов һәм Әхмәров җитәкчелегендә бөтен эш дәверендә Ленин, Сталин һәм партиянең мөһим ма-

териалларын татарчага тәрҗемә иткәндә, җинаятьчел корткычлык белән шөгыльләнде.

Тәрҗемәләрдә корткычлык характеры күренеп торса да, комиссия һәм өлкә комитетының элекке җитәкчеләре берниндидә чара күрмәделәр. Комиссиянең тәрҗемә практикасы нигезендә Сәлах Әтнәгулов, Рәхмәтуллин һәм Газыйм Касыймовлар эшләгән әсәрләрдә революцион марксистик эчтәлекне юкка чыгару концепциясе ята иде. Партия әсәрләрендә механик, чуалчык тәрҗемә кылу юлы нәтиҗәсендә аерым сүзләрнең, җөмләләрнең мәгънәләре бозылды. Инде Исхак Рәхмәтуллин, Әтнагулов һәм башкаларның йөзе ачылгач та, аларның тәрҗемә эшләре Әхмәров, Дәүләтъяров, Хәйретдинов имзалары астында тулысынча яки өлешчә басылып чыгуларын дәвам иттерелде. 1935 елдан, әллә 1936 елдан башлап Дәүләтъяров Таттосиздатта редактор  һәм партия комитеты секретаре булып эшли башлады. Шушы көннән алып, үзенең кулга алынуына кадәр...

Алемасов эчтән генә көлеп куйды. Әле Дәүләтъяров үз кабинетында исәнгерәп утыра торгандыр. Үзе турында язылганнарны укып чыкса, шыр җибәрер иде.

Шул чагында сәркатип кереп, өстәлгә калын гына папка салды:

— Халык комиссарлары советы рәисе иптәш Дәүләтъяровның хуҗалык үсеше перспективалары хакындагы доклады. Сезнең өчен махсус хәзерләгән. Танышып чыгуыгызны үтенде.

— Үзе кайда йөри әле?

— Кабинетында эшли. Докладны сәркатибе аша җибәргән.

«Сизенә, мөртәт, башка көнне булса, үзе йөгереп килеп җитәр иде. Мыштым гына сәгатен көтеп утыра. Михайлов дөрес эшли, эт талаган нәмәрсә, контрларны кулга алынганчы ук морально «эшкәртә» башлый». Алемасов, сәркатипкә төксе карап, чыгып китә аласың дигәнне аңлатып, баш какты.

Папканы ачып, чыгышның беренче битләренә күз йөртеп чыкты. Астан гына үзен күзәтеп утырган Михайловка эндәште:

— Грамоталы, каһәрең, үгезне мөгезеннән эләктергән. Йә, Вася, бу бәндәне нишләтәбез?

Михайлов папкасыннан бер кәгазь алды.

— Озакламый аның күршесендә утыручы Хәкимов Абдулла Хәбибулловичны кулга алырга киләләр... НКВД сотрудниклары Самарин белән Коротичка боерык бирелде. Аның эш кабинетында тикшерү үткәрәләр, Дәүләтъяров аңа пүнәтәй-шаһит буларак катнаша. Өйрәнә торсын, «эш»кә әзерли башладык без аны.

— Хәкимов? — дип сорады Алемасов, нигәдер риза булмыйчарак.— Халык комиссарлары рәисе урынбасарымы?

— Әйе, Александр Михайлович, корткычларны төбе-тамыры белән юк итәргә кирәк. Бу мәсьәләдә икеләнү — смерти подобно икәнен яхшы аңлыйсыз.

— Анысы шулай. НКВД күзлегеннән караганда, диюем... Элек мин дә шулай уйлый идем, шушы постка утыргач, кайбер чакта башкачарак та фикер йөртергә туры килә. Кем белән эшләргә? Ә эш муеннан. Алар янына камерага йөртергә аерым кеше билгеләргә туры килмәгәе, дим. Хезмәт вазифасын кем дә булса башкарырга тиеш бит.— Ул әле генә Дәүләтъяров әзерләп бетергән, тышына олы хәрефләр белән «Алдагы елга халык хуҗалыгы үсеше перспективалары» дип язылган папкага төртеп күрсәтте.— Менә күпме язып тутырган Дәүләтъяров. Чыда гына. Кем эшләр дип уйлады микән?

— Кәгазь түзә ул. Укысаң, җыен чүп-чардыр әле.

— Акыл бар анда барлыгын. Шунысы белән куркыныч та ул. Татарларда шундый әйтем бар: кадак даганы, дага юрганы, юрга батырны, батыр илне саклый. Төшендеңме?! Ничек үрелгән үзара яклашу. Бу халык берләшә калса, утлы күмердә ялантәпи биетәчәк дөньясын. Бәхеткә, берләшү дигән нәрсә алардан әлегә бик ерак, читтә йөри. Дәүләтъяров кебек акыллы башлары булган халык пүчтәк халык түгел ул, иң беренче чиратта халыкның «акыл казанын чистартырга» кирәк, шунсыз тынычлык урнашмаячак бу республикада.

Алемасов янәдән Габит Низамның «күрсәтмәләре»н кулына алды. Үзенең колак төбендә Михайлов әйткән, әмма чекистлар арасында еш ишетелгән «ялган — һөнәр ул!» дигән сүзләр яңгырагандай булдылар.

Тәк, кайда калган иде әле ул? Ә менә, «кулга алынганга кадәр» дигән җирдә. Дәүләтъяров Хәкимовны «озатып» йөри булып чыкты бит әле, бәлки инде Хәкимов төрмәдә Дәүләтъяровка каршы күрсәтмәләр дә бирә башлагандыр. Чуртым белсен бу Михайловны, елгыр адәм. Ашыга төшеп укый башлады.

— Кулга алынганга кадәр Дәүләтъяров, югарыда санап кителгән кешеләрдән тыш, Мөхсинов, Гыймранов Зәки, Вәли Шәфигуллин, Толымбай, Гомәр Гали, Гомәров, Ләбиб Гыйльми, Мәхмүт Галәү, Шамил Усманов, Кәрим Тинчурин һәм башка милләтче пантюркистлар белән элемтәдә торды.

Партком секретаре булып эшләгән чорда Дәүләтъяровка телдән һәм язма рәвештә культура-идеология фронтына оялаган троцкийчылар, буржуаз-милләтчеләр һәм башка икейөзле бәндәләр хакында сигналлар кереп торды (моны Татгосиздатның махсус секторында эшләүче Фәтхуллин раслый ала). Әмма Дәүләтъяров әлеге сигналлар буенча тулы

җавапсызлык күрсәтте, шул рәвешле ул дошманнарны фаш итүдән саклап калды.

Дәүләтъяров контрреволюцион оешмага тартылганмы, юкмы, белмим, чөнки ул үзе дә, башкалар да миңа бу хакта әйтмәделәр. Әмма Татгосиздатта эшләгәндә, Дәүләтъяров корткычлар кылган гамәлләрне ликвидацияләү юнәлешендә кискен һәм большевистик чаралар күрмәде, ул гына да түгел, һәрчак фаш ителгән яки ителеп өлгермәгән контрреволюцион милләтче элементларга таянып эш йөртте. Ул китап нәшриятында эшләгәндә, буржуаз милләтчеләрнең әсәрләре һәм алар төзегән дәреслекләр күпләп чыга башлады.

Мөхәммәтҗанов белән Әхмәров Дәүләтъяров хезмәтен уңай бәяләделәр, турыдан-туры аларның җитәкчелегендә эшләде ул.

Минем үземә шәхсән соңгы ике елда Максим Горький һәм Пушкин, башка классикларның әсәрләрен бастырып чыгару мәсьәләләре буенча берничә мәртәбә Дәүләтъяровның эш кабинетында булырга туры килде. Советлар Союзы язучылары исеменнән художестволы әдәбият әсәрләрен бастырып чыгаруны яхшырту, яшь язучыларның китапларын чыгаруны оештыру мәсьәләләрен күтәреп, шактый таләпләр куйдым. Партия оешмасы секретаре буларак та мөрәҗәгать иттем, һәм Мөхсинов, Толымбай, Гомәр Гали кебекләрнең икейөзлеләнеп йөрүләрен ачып салырга кирәклеген әйттем, буржуаз-милләтче эшчәнлеге өчен Шамил Усмановны җавапка тартырга кирәклеген күрсәттем. Пушкин, М.Горький әсәрләрен чыгарганда җибәрелгән производство брагы өчен гаеплеләрне җавапка тарту мәсьәләсен кискен рәвештә берничә мәртәбә күтәреп карадым. Әмма Дәүләтъяров, вәгъдә бирсә дә, бернәрсә дә эшләмәде. Фурмановның «Чапаев» (тәрҗемәчесе — Рәшит Хәмиди), Новиков-Прибойның «Цусима» (тәрҗемәчесе — Зәки Гыймранов) әсәрләрен татарчага тәрҗемә иткәндә җибәрелгән корткычлыклар турында конкрет сигналлар алынуга карамастан, ул бернинди дә чара күрмәде. Болар барысы да рус һәм совет әдәбияты классикларының тәрҗемәләрен бастырып чыгару мәсьәләсендә Дәүләтъяровның буржуаз-милләтче позициясендә торуын раслыйлар.

Минем белән сөйләшкән чакларда Дәүләтъяров үзен большевик итеп күрсәтергә тырышты һәм аннан нинди дә булса контрреволюцион сүзләр ишетмәдем. Әмма шушы протоколда теркәлгән фактлардан чыгып, мин аны культура-идеология фронтына Абдуллин белән Мөхәммәтҗанов тарафыннан куелган кеше дип саныйм.

Башка аның хакында ни дә булса әйтә алмыйм».

*Габит Низам.*

Алемасов, канәгать төстә Габит Низам «күрсәтмәсе» язылган беркетмәне папка астына салып, икенче беркетмәгә үрелде.

Бусы Гомәр Байчурин сүзләре, бүгенге төннең «эш» нәтиҗәсе икәнлеге күренеп тора. Беркетмәгә берничә урында Байчуринның әллә яше, әллә тире тамган, кәгазьдә ныклап кибәргә өлгермәгән тап эзе ярылып ята. Алемасовның янә кулы кычытып, тәнендә ут уйнап алды. Тоткыннарның сорау алганда «махсус» алымнардан соң, аяк астында аунап, ялынып-ялварып, елап ятулары күз алдына килеп, авызына сулар йөгерде. Эшли белсәң, һәр эш канәгатьлек китерә шул. Бүген «Черек күл»гә барып, подвалда берәрсен «биетеп» кайтмый булмас. Ширәне дә шунда чакыртсаң бигрәк тә шәп була. Кыз инде өйрәнгән, тоткынны стенага йөзе белән сугып тезләндерәсең дә, Ширәне аның сыртына атландырып… Эх-ма, рәхәт минутлар була дөньяда!

Алемасов, төкереген йотып, Байчурин үзе кул куйган күрсәтмәне укый башлады. Сорау алучы НКВД лейтенанты Марголин алай тоткынга уңга-сулга тайпылырга юл куймый. Эшен белеп, шәп башкара.

— Сезнең пантюркистик оешмагызга Дәүләтъяровның нинди катнашы бар?

— Утыз алтынчы елда Татгосиздатта Зәки Гыймранов җитәкчелегендә контрреволюцион-милләтче оешма тар-мар ителгәч, мин бу хакта Мөхәммәтҗанов белән сөйләштем. Әлеге әңгәмә процессында, Татгосиздатта антисоветчыл эшчәнлек перспективасын тикшердек. Һәм шунда Мөхәммәтҗанов миңа бу участокны, Әхмәров белән Дәүләтъяров җитәкчелегендә пантюркистик төркем оештырып, яңадан нығытуын әйтте. Әлеге төркемнең практик эшчәнлегенә бәя биреп, Мөхәммәтҗанов боларның Гыймрановка караганда шәбрәк тә эшләүләрен әйтте.

— Дәүләтъяровның практик рәвештә тормышка ашырган эш-гамәле нәрсәдән гыйбарәт?

— Мөхәммәтҗанов белән сөйләшкәндә, бу темага кагылышлы детальләр хәтердән чыккан. Дәүләтъяровның үзен 1937 елның мартына кадәр белмәдем, күзгә-күз очрашырга да туры килмәде. Мөхәммәтҗанов аны еш мактый иде һәм үзенең ышанычлы кешеләреннән чутлады.

Мөхәммәтҗанов үзе әйткәнчә, Дәүләтъяровны «Кызыл Татарстан» газетасы редакторы итеп күтәрү һәм ВКП(б) ӨК әгъзасына тәкъдим итү аның инициативасы буенча, антисоветчыл төркем әгъзасы буларак оештырылган.

Инде Мөхәммәтҗановның үз күрсәтмәләренә чират җитте. Әмма бүген төнлә Шелудченко белән Крохичев оештырган сорау алу беркетмәсендә аһ итәрлек яңалык юк иде. Мөхәммәтҗанов Галимнең, үзен яшьләрнең «әтисе» дип йөргән кешенең, Татарстанда абруйлы фигураның Дәүләтъяров турында әйтеп үткән фактлары акылга сыймас дәрәҗәдә сай иде. Шул ук

Кызыл Йолдыз районында партия документлары алыштыргандагы гөнаһлары, китап нәшриятында кылган корткычлыклары санап үтелгән, һаман да шул бер балык башы — «халык дошманнары»н фаш иткәндә боргалануы, Толымбай кебек милләтчеләрне канат астына алуы тезеп кителгән. Бер генә яңалык бар, Алемасов тарафыннан килгән куркынычны сизеп, үзен «дошман» буларак Михайлов кулына эләгәсен төгәл белгән Мөхәммәтҗанов ХКС рәисе булып эшли башлаган Дәүләтъяров янына кереп зарланып чыккан. Тегесе «остазын» саклап калу юлында кулыннан килгәннең барын да эшләргә сүз биргән. Бусы кызык, әлбәттә, һәм монда бернинди арттыру, ялган да юклыгы көн кебек ачык. Кулга алыныр алдыннан Мөхәмммәтҗанов үзе дә, Дәүләтъяров та аның тирәсендә йөгерештеләр, «ышанычлы иптәшләрне саклап калу мәсьәләсендә сөйләшәсе бар» дигәнрәк үтенечләр белән аның кабинетында тоткарланырга тырыштылар. Алемасов аларга борчылмаска, тыныч кына эшләргә кушты, үзе исә моментны көтте. Егерме дүртенче октябрьдә инде Галим төрмәдә, «халык дошманы» булмавын исбат итеп, күлмәк ерта иде...

Мөхәммәтҗанов Дәүләтъяровның иректә икәнен белә, аның яклавына өмет итә, шуңа күрә гаепләү ягына килгәндә, билгеле фактларны гына чыгарып салырга тырышкан. «Барыгызга да бер юл, нигә анда әллә нинди хәйләләргә бармыйсыз, тирегезне салдырып, башмак итеп киячәкбез! Котылу юк сезгә!»

Алемасов янә кәгазьләргә иелде, Михайлов исә кәнәфигә җәелеп утырган да йокымсырап киткән иде. Алемасов кызганып куйды. «Авыр, Тулага караганда ун мәртәбә авыр Казанда эшләве. Милләтчеләрдән дә явызларча тартышучы, каршылык күрсәтүче хәшәрәтләрне күргәне булмады аның».

Кулга алынганчы ВКП(б) ӨК фән һәм мәктәпләр бүлеге мөдире булып эшләгән Фазыл Рәхмәтуллинның күрсәтмәләренә ул инде битараф рәвештә өстән генә күз йөгертеп чыкты. Истә калырлык факт шул, күпләп кулга алулар башлангач, Дәүләтъяров Рәхмәтуллинга милли кадрларны саклап калырга тырышырга кирәклеге хакында сафсата саткан икән. Күренгәнчә, Мөхәммәтҗанов дөрес эш йөрткән, бу мәлдә ХКС рәисе итеп тәкъдим итү өчен Дәүләтъяровтай нык холыклы, сак эш йөртүче һәм ышанычлы, белемле башка кеше булмаган дисәң дә дөрестер. Дәүләтъяров тамыр җәйсә, Мөхәммәтҗанов ишеләргә ныклы терәк булачагын яхшы аңлаган, мөртәт...

Папканы ябып, Беренче озын, шома өстәл буйлатып аны Михайловка шудырып җибәрде. Тегесе сискәнеп күзен ачты.

— Кайчан кулга аласыз? — Алемасовның карашы төксе иде.

Михайлов сәер генә кымшанып алды.

— Кемне?

— Койрыклы женне! Дәүләтъяровны кайчан «Черек күл»гә озатырга җыенасың?

— Төнгә кадәр утырсын әле, күке кычкырганын көтеп. — Михайлов, йокысын бүлгәнгә көйсезләнгән сабый сыман, үпкәле җавап кайтарды. — Әллә тиз чишелер дисеңме?

— Минемчә, андагы хәлләрне чамалый ул. Бераз тузанын каккач, теле чишелер. Судны көтеп алып, шунда барысын да сөйләп биреп, мәсьәләгә ачыклык кертергә ният итеп ятучы шомалар да бар. Дәүләтъяров та шуңа исәп тотар, мөгаен. Совет иленең иң гадел хөкеменә өмет итүче бичаралар...

## XIII

Ноябрьнең соңгы тәүлегенә аяк бастык... Тәрәзә артында кыш җиле бөтерелә. Әхмәтсафа Хәкимовның кабинетын тентүдә катнашканнан соң, бөтенләй уйсыз-фикерсез кешегә охшап калган иде. Сәркатипнең кабинет ишегеннән башын тыгып өзә-төтә саубуллашып кайтып киткәненә шактый вакыт үтте. Сәркатипнең соңгы сүзләре бәгырьне тырнап тора:

— Сезгә, иптәш Дәүләтъяров... көтеп торырга куштылар... Хушыгыз, Сафа абый...

Әйтмәсә дә белә иде. Барыбер бәгырьне сораулар өзгәли. Кем кушкан, ни өчен үчектеләр аңа? Беркемнең юлына аркылы төшмәде, җәдәлләшеп, явызлык кылып йөрми, беркемгә аяк чалмады кебек, кирәк-кирәкмәс бәхәскә кергәне юк, башкаларга ләгәнләп пычрак ударганда да, ул бичараның язмышын җиңеләйтергә тырыша, эштән чыгарып ташланган язучыларга, журналистларга алдан акча биреп тору тәртибендә эш-йомыш тапкан булып ярдәм кулы сузды, гаиләләрен ач үлемнән коткарып калды. Ярдәм алучылар, рәхмәт, берсе дә сатмады, китап нәшриятында, «Кызыл Татарстан»да бергә эшләгән хезмәттәшләре арасында Әхмәтсафаның бу гамәлләрен белүчеләр булды, әмма алар да эндәшмәде. Яшь милли кадрларны үстерү, булганын саклап калу мәсьәләсендә Әхмәтсафаның позициясен күпләр үз итте.

Халык комиссарлары советына күчкәненә ике ай да унсигез көн, нинди дә булса гаеп тагарлык эш күрсәткәне булмады, вазифасына да яңа кереп бара. Чоры катлаулы, вазгыять аңлаешсыз, мондый шартларда яңа эшкә керешеп китүченең хәле билгеле инде. Бүлекләрдә башлыча яңа кешеләр, аларны сабыр гына эш җаена өйрәтү өчен дә күпме вакыт кирәк. Кешеләр дигәннән, ул бөтенләй ялгыз хис итте үзен монда күчкәч. Үз тирәсендә кайнашкан кемгә таянырга була? Кабинетына кереп-чыгып йөрүчеләр, озын коридорда тызбыз юргалап үтүчеләр бихисап, ә янәшәдә сөйләшер, аңлашыр, кирәк чакта эч серләрен бушатырга беркем юк. ВКП(б) ӨК матбугат бүлеге мөдире булып эшләүче Әхмәров Абдул-

ла белән серләре килешә иде, аны да кулга алдылар. Михайловның мактанып сөйләгәнен үзе ишетте:

— Мөхәммәтҗанов белән Әхмәров кадәр дә ачылганы булмады инде. Ну әле аларны сыгасы да сыгасы. Җепнең очы шушы хәшәрәтләрдә булырга тиеш.— Нарком иренен чалшайтып елмайды да, туп-туры Дәүләтъяровка карап алды.

Димәк, кыйнау, җәзалауларның мөмкин булган бөтен алымнарын шушы ике бичараның газиз башлары, тәннәре, җаннары күтәргән... Моны Әхмәтсафага тәфсилләп аңлатып торасы юк иде.

...Кабинет суынды. Тәндә җылы калмады кебек. Ул пәлтәсен иңсәсенә салмакчы иде, кире уйлады. Кемгә хаҗәт аның исәнлеге, саулыгы? Кайларда аунарга туры киләчәк аңа якын көннәрдә? «Черек күл»гә килеп эләксәң, аннан ычкынуы икеле. Өмет бар барын — чөнки иманы камил, аның партия, совет хөкүмәте каршында да, җитәкчеләр алдында да бер гаебе дә юк. Әмма гаепсезлек иң зур гаеп санала, ахры, бу заманда...

Тәрәзә каршына килеп басуы бүген ничәнче мәртәбә булгандыр, исәбе юк. Урамда, тәрәзә караган якта сүрән ут яктысында кар сибәләве күренде. Әле Яңа Чишмәдә чакта ук беренче кар төшкән иде, бүгенгесе ныклап җиргә ятарга чамалый, ахры.Тирә-юнь серле аклыкка күмелеп бара. Кар барысын да күмә, һәрнәрсәне үз кочагына ала, күзгә күренмәгән һәрнәрсә юкка чут бит ул. Кеше гомере дә шул инде, җир җимертеп яшәгәндә, хезмәт вазифасы биләгәндә син бар, кулдан эш китсә, син юк инде. Оренбурда гомер агышы, нәсел җебе хакында акыл биргән Гомәр агасы — агабзыйсы искә төште. Яшәде Гомәр ага, атаклы шәхесләрнең үз кешесе, сердәше булды, булган мал-мөлкәтен совет хөкүмәте тартып алып, шыр ялангач, ятим калды. Үзенә күпме игелекләр эшләгән агабзыйсы янына барырга да вакыт тапмаган хөрәсән бит ул. «Эш, эш», имеш. Үзеңнең дә, эшеңнең дә кемгә хаҗәте бар бүген менә? Кемдер: үкенәсең килмәсә, берәүгә дә игелек кылма, дигән. Гомәр агай алай үкенеп яшәмәде кебек, соңгы еллары ничек үткәндер, анысын инде ул белми. Агабзыйның дөнья куйганы турында хәбәр ишетүенә кайчан, кайтып каберенә зиярәт кыла алмый калды. Үкенечләр, үкенечләр... Үкенечләрен барлап утырудан да мескен адәм юктыр дөньяда. Гомәр агай, Мифтах хәлфә, Нургали Надиев... Аның күзләрен дөньяга ачкан кешеләр шулар булды. Ә яшьләрдә миһербан җитенкерәми. Кайсының гына хәлен белде ул, кайсына гына рәхмәт әйтеп өлгерде? Юк бит. Их, хәтере кыска адәм баласының. Менә бу болганчык дәверне исән-имин кичеп чыга алса... Белер иде дә ничек яшәргә, исән калулар икеле шул, икеле... Күңелен бераз тынычландырганы шул — ике улы үсеп килә. Гомәр агай әйтмешли, җөзәнең – нәсел җебенең өзелмәсенә нык ышана ул. Хәтта ки кешеләр ал-

дында бераз гаебе дә булсын ди, Ходай каршында да бераз гөнаһысы бардыр, адәм баласы хатадан хали түгел, ул гаеп-гөнаһлар өчен битәрләгән кеше юк бит аны. Бөтенләй башка нәрсә — яла ягуга нигезләнгән, акылга сыймаслык хаталар дигән булып, бәгырьне корыталар. Шунысы сәер. Ил белән шушы сәясәт бара, ил белән нахак бәла тагыла кешеләргә, кылмаган гөнаһ-гаепләр өчен җәзага тартылып күпме җаннар кыелды. Моңа кайчан да булса чик куелырмы? Исең китәр, милләтчелектә гаепләп күпме асыл егетләрне «Черек күл»гә илтеп тыктылар, берсенең дә кире кайтканы юк, ул гына түгел, август башларында бик күбесен атканнар икән дигән хәбәрләр дә колакка чалынды. Беркем беркемне якламый, дәшми, чаң сукмый, ә «Черек күл»нең төбе кара, тирән, йота гына тора адәм балаларын.

Куркыныч үзен читләп үтәр дип йөрде, күп нәрсәгә күз йомды Әхмәтсафа, белмәгән булып кыланды, инде үзенә чират... Аның юкка чыгуына да аптырап, чаң сугып йөрүче булмаячак. Әйтерсең алар кешеләр түгел, ат тәгәрмәче сытып үткән бөҗәкләр генә. Җанда — бөҗәкләр гөжләве, бөҗәкләр сулкылдавы, бөҗәкләр елавы, бөҗәкләрнең акылдан шашып көлүе... Тәрәзәгә бәрелә-сугыла кар бөртекләре оча. Кар бөртекләре тәгәрмәч астында калган җансыз бөҗәкләргә караганда күпкә бәхетлерәктер әле... Милләтнең бөтенлеге, бердәмлеге, алга китеше хакында кайгыртып йөрү начарлык буламы? Милләт нәрсә дә, милләтче кем ул — бу хакта да ныклап уйланган кеше юк. Хәер, уйланып кара, хәзер төпсез күлгә чумачаксың.

Уйларыннан арынып, сискәнеп китте. Коридорда каты басып килүче аяк тавышлары ишетелде. Ул ашыгып стенадагы сәгатькә күз салды. Сәгать телләре, көн уртасына җитеп, хәрәкәтсез туктап калган иде...

Кабинет хуҗасы, ниһаять, көтеп торуга нокта куелды дигән уйдан беркадәр җиңеләеп, стена буена тезелгән урындыкка барып чүмәште. Бетте, барысы да артта калды. Алда...

Кисәк ишек ачылып китте, кабинетка өч хәрби килеп керде, берсе, каушап калган Әхмәтсафа Дәүләтъяров каршына килеп:

— Дәүләтъяров сез буласызмы? — Җавап көтеп тормастан әмер бирде.— Киенегез! Сез кулга алындыгыз! — Әхмәтсафаның каушап калуыннан сөенгән кебек, уйнак тавыш белән кулындагы кәгазьне болгап алды.— Менә ордер. Без, НКВД хезмәткәрләре лейтенант Самарин һәм Павалей, махсус боерык буенча килдек...

Әхмәтсафа, сабыр булырга тырышып, урыныннан кузгалды. Йөзенә үзен кулга алырга кемнәр килүе бөтенләй кызыксындырмаган кыяфәт чыгарды.

Хәзер генә чамалап алды, кулына пәлтәсен тотып тора

икән. Кайсыдыр пәлтәне кулыннан алып кырыйдагы урындыкка ташлады.

НКВД хезмәткәре, дәүләт куркынычсызлыгы лейтенанты Самарин, хезмәттәше Павалейга әмер бирде:

— Пүнәтәйләрне алып кер!

Кабинетка Үзәк Башкарма Комитеты әгъзасы полковой комиссар Николай Хәбибуллин, үзенең урынбасары Аркадий Новоселовны керттеләр. «Аларны да кабинет саклап ятарга мәҗбүр иткәннәр икән». Әхмәтсафа, үз хәлен онытып, әлеге ике кешене кызганып куйды. Аягы калтырауны баса алмый урындыкка шапылдап утырды, аңа әһәмият бирүче булмады.

Самарин кабинет түренә үтеп, өстәл артына килеп басты һәм кулга алу турындагы карарны кычкырып укый башлады:

— 1937 елның егерме тугызынчы ноябре көнне, мин Татарстан республикасы НКВДсына караган дәүләт куркынычсызлыгы идарәсенең дүртенче бүлеге, беренче бүлекчәсе сержанты Черпаков, 1905 елда Оренбур өлкәсе Сакмар районы Каргалы авылында туган, ВКП(б) әгъзасы, татар, СССР гражданы, совнарком рәисе булып эшли, Гоголь урамы егерме бишенче йортта яшәүче гражданин Мостафа улы Әхмәтсафа Дәүләтъяровка кагылышлы материалларны карап чыкканнан соң, Дәүләтъяров совет хакимлеген бәреп төшерү максаты белән оештырылган контрреволюцион милләтче-пантөркичел оешмада тора дип таптым…

…Йа Ходa, кем ул Черпаков, аның кулына кем биргән бу уйдырма язып тутырган кәгазьне! Нәрсә эзләгән дә ни тапкан? Менә ничек әвәләнә икән ул гаепләүләр! Әхмәтсафаның чатнап башы авырта башлады. Ул ике кулы белән башын тотып утыра бирде.

Самарин ашыга-кабалана ниндидер ике ятып бер төшенә кермәгән Черпаков дигән сержант язганнарны укый:

— Озак вакытлар дәвамында шушы контрреволюцион оешмада торган хәлдә Дәүләтъяров ВКП(б) сәясәтенә һәм совет хакимлегенә каршы юнәлдерелгән, РСФСР җинаять кодексының унҗиде дә илле сигезенче статьяның сигезенче искәрмәсе, илле сигез дә унберенче статьяларга туры килүче контрреволюцион эшчәнлек алып барган.

Шуларны искә алып, югарыда күрсәтелгән статьялар буенча Мостафа улы Әхмәтсафа Дәүләтъяровны кулга алырга һәм тентү үткәрергә карар кабул иттем.

Беренче санлы төрмәдә сак астында тотарга…

…Җанны авыр уйлар басып китте. Әйләнә-тирәне соры томан каплады, шушы шыксыз эңгердә коточкыч тизлектә бөтен гомере зырлап үтеп китте шикелле, айкалган-чайкалган күңел түрендә бер мәлгә Рабига, балалары чагылып алды.

— …Түзегез, җаннарым… — Әхмәтсафаның эчтән әйтелсә дә, тышка бәреп чыккан иңрәүле тавышы Самаринны

бүленергә мәҗбүр итте. Ул аптыраган карашын Павалейга юнәлтте.

— Укып бетер!.. — диде Павалей, риза булмаган тавыш белән. — Барысы да тәртиптә...

Самарин арыган тавыш белән дүртенче бүлек башлыгы дәүләт куркынычсызлыгы капитаны Шелудченкодан ризалык алынуын, карарга беренче бүлекчә түрәсе Марголин кул куйганлыгын, нарком Михайлов белән килештерелгәнен хәбәр итеп, кәгазьне Павалейга сузды.

— Тотак кул куйсын...

Бу хәлдән тетрәнеп калган пүнәтәйләргә карап алганнан соң, Павалей төксе генә Дәүләтъяровка эндәште:

— Килегез, кул куегыз...

Әхмәтсафа, нык торырга тырышып, өстәлгә якынайды. Йа Хода, шушы ахмаклыкка ышанучылар бар микән? Ул инде мондый гаепләүне бүген бер ишетте — Хәкимовны кулга алганда. Хәкимов кулга алу турында кул куйганда ишетелер-ишетелмәс итеп: «Мин гаепсез...» — дигән иде.

Ирексездән шушы сүзләр Әхмәтсафа иреннәреннән дә тәгәрәп төштеләр.

— Мин гаепсез...

Самарин дәшмәде, кул куелган кәгазьне, өстәлдән алып, папкасына шудырды, үзе Павалейга боерды:

— Өстәлдәге бөтен кәгазьләрне җыйнагыз!..

...Ярты сәгатьтән ул инде «Черек күл»дә тикшерүче Крохичев белән НКВД наркомы урынбасары Шелудченко алдында аягыннан түшәмгә асып куелган хәлдә тора иде.

Аны төне буе кыйнадылар. Кыйнап арыган арада, кан баскан күзләрен мәҗбүри ачтырып, борын төбенә кәгазь төртәләр. Крохичев беләгенә тамган кан-сүлне Әхмәтсафаның канлы күлмәк якасына сөртеп ысылдый:

— Кул куй, заразы, күпме интегергә була синең белән, хәшәрәт!

Җимерелгән яңак сөяген көчкә кыймылдатып, Әхмәтсафа һаман бер үк сүзләрне кабатлый.

— Җәфаламагыз, минем гаебем юк...

Шелудченко, шуны гына көтеп торган кебек, аны янә сугып екты, типкәләргә тотынды. Крохичев, хәл җыеп, чәй эчеп, бу күренештән ләззәт алып утыра. Үзе сөйләнә:

— Вәт, эт җан, ничекләр карыша бит. Мөхәммәтҗановтан уздыра бу болай булса... Тагын нәрсә кыландырабыз, Матвей Иванович?

— Телен тешләтеп өздергәнче ярабыз, шул аның даруы... Әле контрлар белән башкача сөйләшкәнне белмим. — Шелудченко ярсый-ярсый тотакны типкәли бирде. — Мә сиңа, милләтчелек... Мә сиңа, пантөркичелек... Мә сиңа, контрлык!

Төне буе, көне буе кыйнадылар аны. Ничә мәртәбә аңын

җуйган, ничә мәртәбә һушына килгән — үзе түгел, аны җәзалаучылар да исәбен югалтканнар иде инде.

Җәзалау барышында бүлмәгә берничә мәртәбә Михайлов кереп чыкты, әле һаман гаепләү кәгазенә кул куймавын белгәч, йөзе бозылып, теш арасыннан:

— Эшли белмисез! — дип, кискен хәрәкәт ясап, кул кыры белән тотакның муенына китереп сукты. Хәлсезләнеп беткән Әхмәтсафа, урындыктан очып, стенага барып сыланды. Михайловның йөзенә кәпрәюле елмаю кунаклады.— Менә шулай кисәләр аны. Сез монда аның белән нәрсә кыланмакчы була торгансыздыр, аңламыйм,— дип, идәндә ыңгырашып, тартышып яткан Әхмәтсафа өстеннән атлап чыгып китте.

Тәүлек эчендә аның бер күкәйлеге сытылган, ике тапкыр кумаклы базга салып алганнар, күкрәк тактасы урыныннан купкан, тәндә кыйналмаган, изелмәгән төш калмаган, тешләре коелып беткән, монда килеп кергәндәге кара-коңгырт чәчләре ап-ак иде...

Аның бу җәза машинасына каршы торырлык хәле калмаган иде. «Теләсә нинди контрны ярты сәгать эчендә кул куярлык хәлгә җиткерәм»,— дип мактанган Крохичевның бар түземлеге төкәнде. Ул инде ни кыланганын белештерми тукмый иде тотакны. НКВД подвалында шушы тәүлек эчендә тагын бер кеше шәхес буларак үлде, әлегә йөрәге тибүдән туктамаган җан иясе генә калды. Бу инде НКВД телендә йөргәнчә, тиешенчә «эшләнгән» материал иде...

Кул бармакларын изеп бетергәч, Әхмәтсафага «ял» бирделәр. Һуш җыеп, әйткәнне аңлар хәлгә килгәч, Крохичев иягеннән нык итеп тотып башын артка каерды:

— Карышма, эт токымы, соңгы тапкыр кисәтәм, мин әйткәннәрне кәгазьгә төшерсәң, исән каласың, хатының, балаларың янына кайтасың, карышсаң, капут сиңа! Аңладыңмы, өеңә кайтасың киләме?

— Өйгә кайтарыгыз...— дип ыңгырашты Әхмәтсафа.

Крохичев, Шелудченкога күз кысып, елмайган булды:

— Әллә кайчан шулай диләр аны, синең монда нигә кирәгең бар? Язасың, кул куясың да, әллүр, өеңә сызасың!

Шелудченко тотакның кулына каләм сузды. НКВДның җәза машинасы максатына иреште — 1937 елның беренче декабрендә, таң алдыннан Әхмәтсафа Дәүләтъяров җаһил Крохичев әйтеп торган сүзләрне шәмәхә кара белән кәгазьгә төшерә башлады:

«Нарком Михайловка тикшерү тотагы Дәүләтъяровтан.

Минем эшем буенча кузгатылган тикшерүне һаман да сузуның мәгънәсезлеген аңлап һәм карышудан туктарга кирәклегенә төшенгәннән соң, үземнең советка каршы эшчәнлегем хакында ачыктан-ачык белдерергә кирәк дип таптым.

1936 елда Татарстан дәүләт нәшриятына эшкә килгәч,

баш редактор Әхмәров белән дуслаштым, аның коткысы белән һәм аның тарафыннан шәхсән үзем бүгенге көнгә кадәр актив катнашкан советка каршы милләтчел оешмага тартылдым. Аңлашылганча, минем соңрак газет редакторы, аннан өлкә комитеты әгъзасы итеп сайлануым очраклы түгел иде. Бу эшләр Мөхәммәтҗанов кулы белән тормышка ашырылды һәм советка каршы үзәк җитәкчеләренең берсе булган Лепа тарафыннан яклау тапты.

Үземнең һәм мин белгән кешеләрнең советка каршы эшчәнлеге хакындагы күрсәтмәләремне кабул итеп алуыгызны сорыйм».

Шелудченко тотакның язганын алып укыды да, аның алдына машинкада басылган берничә кәгазь китереп салды.

— Күптән шулай кирәк иде, хәшәрәт. Хәзер боларына кул куй!

— Минем гаебем юк... — диде Әхмәтсафа, барлык авыртуларын онытып, урыныннан калкына төште.

— Без гаепсезләр белән булышмыйбыз, контр! — дип, Крохичев Әхмәтсафаның касыгына китереп типте. — Әйт, син гаеплеме? — Ул идәндә бөгәрләнеп яткан тотакның аягына элмәк кигертә башлады. — Гаеплеме син? — дип җикеренде ул.

Хәсрәтле җавап ишетелде:

— Гаепле...

— Шулай дип кал, кумак базына төшеп менгәч, башкача сөйләшер идең, эт җан!

— Өйгә кайтарыгыз... — диде ыңгырашып тотак һәм аңын җуйды. Өстенә чиләк белән су койдылар. Тотак селкенмәде. Крохичев сүгенә-сүгенә тотакны идәннән сөйрәп алып урындыкка аркылы ыргытты һәм нык итеп артына китереп типте.

Шелудченко Крохичевны туктатты.

— Җитте, бу хәшәрәт белән озак мataштык. Камерага кертеп ташласыннар. Акыл җыеп, рәткә килгәч, ничек сайрар, карарбыз. — Бераз җан әсәре сизелгәнен чамалап, тотакка колагына иелеп иләмсез акырды. — Аң бул, Дәүләтъяров, яшисең килсә, күрсәтмәләреңне үзгәртмә, а то секай башка будет, понял, сука? Әле эшең бетмәде, өйгә кайтмый торасың, тиз бул, шушы битләргә кул куй!

Тотак авырлык белән үзенә сузылган җиде битлек сорау алу беркетмәсен кулына алды, Шелудченко каләм сабы белән нык итеп муен астына китереп төртте:

— Мә, такта чырай, тизрәк кулыңны куй!..

Әхмәтсафа авыртудан бераз дәшми торды, урыныннан купкан яңак сөяген сак кыймылдатырга тырышып:

— Укып чыгарга рөхсәт итегез, — диде.

Шелудченко белән Крохичев мәзәк итеп бер-берсенә карашып алдылар. Алар аптыраушта иде. Шушы изелеп, тапта-

лып беткән адәм, һаман вакыт сузып маташа бит, ә. Ләкин берсенең дә кул күтәреп, янәдән тотакны кыйныйсы килмәде.

— Тиз бул, анаңны...— дип сүгенде Крохичев.— Бер минут вакыт сиңа карап чыгу өчен.

Күзләрне кан баскан, керфекләр эренләпябышып беткәннәр, шулар арасыннан сөзелеп кергән сүрән яктылыкны тотып калырга тырышып, Әхмәтсафа көчәнеп укый башлады.

— Сез советка каршы пантөркичел-милләтче оешмада катнашучы буларак кулга алындыгыз. Үзегезне гаепле дип санныйсызмы?

— Гаепләү дәлилләре мине ышандыра, шуңа күрә карышып маташу мәгънәсезлек дип уйлыйм.

Татарстанда советка каршы актив эшчәнлек җәелдергән пантөркичел-милләтче оешмада торуым сәбәпле, үземне гаепле саныйм.

Тикшерү барышында үземнең һәм миңа билгеле булган башка кешеләрнең советка каршы эшчәнлеге хакында бөтен дөреслекне ихлас сөйләп бирергә булдым.

— Сез кайчан һәм кем тарафыннан советка каршы оешмага тартылдыгыз?

— Пантөркичел-милләтче оешмага мин Таттосиздатның баш редакторы Әхмәров тәкъдиме белән 1936 елның башында кердем.

Әхмәров белән без ТКУда укыганда ук дус идек. Бу дуслык соңга таба да дәвам итте.

Ул чакта ук, үзара ачыктан-ачык сөйләшкәндә, без милли мәсьәләләрдә фирка сәясәте белән килешмәвебезне әйтә идек. Бу сәясәт милли республикаларның мәнфәгатьләренә җавап бирми, Мәскәү республикалар белән санлашмый, хокукларын кыса, аларга карата колонизаторлык политикасын алып бара дигән фикергә килдек.

Без авыл хуҗалыгын коллективлаштыру мәсьәләсенә дә шик белдердек, бу гамәл тормышчан түгел дип инана идек.

Коллективлаштыру ашыгып үткәрелә, крестьян моңа әзер түгел, шунлыктан фирка сәясәте уңышсызлыкка дучар дип санадык.

Тулысынча коллективлаштыру нигезендә, сүздә түгел, гамәлдә бөтен төбәкләрдә кулакларга каршы һөҗүмгә күчкәч тә, без Әхмәров белән фирка сәясәтен якламадык, кулакларны туган җирдән сөрүне бөтенләй кирәксез нәрсә дип таптык.

Әхмәров белән кабат очрашып, Таттосиздатта бергә эшли башлагач, ачыктан-ачык сөйләшүләрне дәвам иттек, ул әңгәмәләр барышында совет хакимлегенә һәм фиркагә карата тагын да ныграк килешмәүчәнлек чагыла иде. Без фиркадә демократиянең булмавын, троцкийчыларга һәм уңнарга карата дөрес булмаган сәясәт үткәрелә, Троцкий, Бухарин ке-

бек шәхесләр тик торганнан эзәрлекләнә, алар үзләренең идеяләрен яклый алмыйлар, авызлары томалана дип саный идек.

Колхозлар төзү барышын анализлап карагач, күмәк хуҗалык ни урыс крестьянына, ни татарга уңайлы түгел, алар анда мәҗбүри тотылалар, аерым хуҗалык нигезендә тормыш алып бару аларга күпкә кулайрак дигән нәтиҗәгә килдек, икенче төрле әйткәндә, шәхси милекчелек позициясендә тордык.

Шундый сөйләшүләрнең берсендә, Әхмәров Татарстанда совет хакимлегенә каршы көрәшүче пантөркичел-милләтче оешма барлыгын, аңа республиканың күп кенә җаваплы работниклары кергәнлеген әйтеп, миңа да бу эшкә кушылырга тәкъдим ясады. Инде советка каршы рухта шактый чарланган кеше буларак, икеләнеп тә тормастан, мин риза булдым.

— Әхмәров советка каршы оешмада кемнәр катнашуын әйттеме?

— Өч кешенең исемнәрен атады ул. Болар — өлкә комитетының икенче секретаре Галим Мөхәммәтҗанов, миңа кадәр халык комиссарлары советы рәисе булып эшләгән Кыям Абрамов, элекке финанс халык комиссары Каюм Мәһдиев.

— Нәкъ менә шушы кешеләр оешма белән җитәкчелек итәләр, диде Әхмәров, бу оешмага элекке «уң» һәм «сул» төркемчеләр тулысынча керәләр, буржуаз милләтчеләр дә тартылдылар, диде ул.

Әхмәров миңа өлкә комитетының беренче секретаре Лепаның шушы оешма белән бер булып эшләвен, аның да Татарстандагы советка каршы уңтроцкийчы оешмада торуын хәбәр итте.

Мин моңа бик гаҗәпләндем һәм Әхмәровтан: «Дөресме бу?» — дип кат-кат сорадым. Ул бу сүзләрнең хак булуын раслап: «Уңтроцкийчы оешма безнең пантөркичел оешма белән тыгыз элемтәдә торган хәлдә советка каршы эшчәнлек алып бара», — дип җавап бирде.

— Советка каршы оешманың бурычлары хакында Әхмәров сиңа ниләр сөйләде?

— Ул миңа бу оешманың төп бурычы — совет хакимлеген бәреп төшерү, төзеләчәк буржуаз Туран дәүләтендә капитализмны кабат тергезү икәнлеген әйтте.

Әлеге бурычны тормышка ашыру йөзеннән оешмада катнашучыларны тиешле урыннарга хезмәткә урнаштыралар, алар анда корткычлык эшчәнлеге алып баралар, үзләре белән эшләүчеләрне милләтчелек рухында тәрбиялиләр, шулай ук яңа кадрларны табып, оешмага тарту белән шөгыльләнәләр.

— Сезгә Әхмәров советка каршы оешманың террорчыл ниятләре турында да әйтте бит. Ни өчен бу хакта дәшми үтәсез?

— Бу хәлне яшерергә бөтенләй теләмәгән идем. Чыннан да, бу оешманың төп бурычларының берсе — фирка һәм совет

хөкүмәте җитәкчеләренә каршы терактлар хәзерләү, аны тормышка ашыру икәнлеген Әхмәров миңа искәрткән иде.

Әхмәровның әйтүенчә, тиешенчә хәзерләнгән һәм уңышлы тормышка ашырылган терактлар бик тә нәтиҗәле була, чөнки аннан соң фирканең сәясәтен тамырдан үзгәртеп, без теләгән юнәлешкә борып җибәрергә мөмкинлек туа, ә инде Сталинны үтерү — совет хакимлегенә каршы восстание күтәреп, аны бөтенләй бәреп төшерү мәсьәләсен хәл итәчәк, дип аңлатты ул.

— Әлеге террористик ниятләр гамәли яктан ничегрәк тормышка ашырылдылар соң?

— Бу мәсьәлә буенча миңа ни дә булса билгеле түгел.

— Татгосиздатта корткычлык һәм дошманлык эшчәнлеге алып бару турында Әхмәровтан задание алдыгызмы?

— Әйе, алдым. Әхмәров мине оешмага тарту турында Мөхәммәтҗанов белән сөйләшкән, Мөхәммәтҗанов минем кандидатурамны хуплаган һәм бергәләп яки Әхмәров кушуы буенча Татгосиздаттагы корткычлык эшчәнлегенә керешеп китәргә тәкъдим итте.

— Мөхәммәтҗановның әлеге дошманый тәкъдимен тормышка ашыру юлында нәрсәләр эшләргә өлгердегез?

— Ул вакытта ук Рәхмәтуллин Исхак һәм Татгосиздатта эшләүче башка милләтчеләр, берләшеп, марксизм-ленинизм классикларын бозып тәрҗемә итә башлаганнар иде. Ә инде Рәхмәтуллинның корткычлыгы фаш ителә башлагач, без аны төрлечә яклап азапландык.

Марксизм-ленинизм классикларын тәрҗемә итү буенча комиссия оештырылган иде. Элекке вәлидовчы һәм милләтче буларак Рәхмәтуллин кандидатурасы ВКП(б) Үзәк Комитеты тарафыннан кире кагылды, без, бу хәлне партоешмадан яшереп, Рәхмәтуллинны Татгосиздатта эшләтә бирдек.

Рәхмәтуллинны кулга алгач, Әхмәров белән икәүләп аның корткычлык эшен дәвам иттек, марксизм-ленинизм классикларын аңлы рәвештә бозып татар теленә тәрҗемә иттек.

1936 елда тәрҗемәдә чыккан Сталинның «Ленинизм мәсьәләләре» китабының тәрҗемәчесе һәм мөхәррирләренең берсе буларак, мин, корткычлык максатыннан, фикерне һәм мәсьәләнең куелышын контрреволюцион бозуга китергәнен белә торып, юри аерым сүзләрне, хәтта фразаларны төшереп калдырдым.

Ә инде «Большевик» журналында «Ленинизм мәсьәләләре» китабын татарча тәрҗемә иткәндә, махсус ясалган бозулар хакында мәкалә чыккач, мин, Татгосиздатта фирка сәркатибе буларак, партҗыелышта аны формаль тикшерүгә юл куйдым, тәнкыйтькә урын калдырмадым, мәсьәләнең сәяси асылын йомшарттым.

Мин, Әхмәровның күрсәтмәсен үтәп, Бурнаш, Мәхмүт Га-

ләү кебек буржуаз милләтче язучыларның чын йөзләрен ашереп калдырырга маташтым, аларны якладым, кычкырып торган милләтчел рухта язган әсәрләрен басып чыгаруга юл куйдым, зур суммада гонорар түләдем. Консультбюро эшен таркаттым, китап басып чыгару планын өздем, Таттосиздатны элеккегә караганда да тирәнрәк упкын ягына өстерәдем.

Элегрәк Таттосиздатта басылып чыккан китаплардагы, мәсәлән, Әтнәгулов төзегән дәреслектәге антисоветчыл юнәлештәге бозуларны тәнкыйть итәм дигән булып, мин юлбашчыбыз Сталинга һәм фиркагә каршы яла ягу, антисоветчыл пропаганда эше белән шөгыльләндем.

— Тикшерү күрсәткәнчә, Сез аңлы рәвештә Таттосиздат аппаратын милләтчел, советка каршы элементлар белән чүпләгәнсез. Бу дөресме?

— Дөрес. Ул чакта Таттосиздатка кереп оялаган һәм инде фаш ителүләре котылгысыз булган ата милләтчеләрне туздыруда бераз катнашкан булып, үземнең чын йөземне яшереп калырга тырыштым. Мин — Дәүләтъяров, алар урынына советка каршы кадрларны эшкә кабул иттем һәм кирәгенчә урнаштырдым. Фаш ителеп кулга алынган «халык дошманы» Шәфигуллин урынына нәфис әдәбият секторы редакторы сыйфатында Таттосиздатта милләтче Толымбай–Шаһиәхмәтовны асрадым. Андыйлар күп иде: Мөхсинов, Галиев, Гыйммранов һәм башкалар.

Таттосиздатның фирка сәркатибе вазифасын башкарган чакта, культура-идеологик фронтта оялап алган троцкийчы буржуаз-милләтчеләр, башка икейөзле бәндәләр хакында телдән яисә язма рәвештә шактый сигналлар алсам да, бернинди чара күрмәдем, аларның «халык дошманы» икәнен яшереп калдым, корткычлык эшләренә күз йомдым.

Совет язучылары исеменнән китапларның басылу сыйфатын яхшыртуга, яшь язучыларның китапларын чыгаруга әзерләү өлкәсендә эшне көчәйтүгә юнәлдерелгән тәкъдимнәр керде; Пушкин, Максим Горький әсәрләренең шөкәтсез полиграфик йөзе хакында, бу эш өчен нәшриятта брак җибәрүчеләрне җавапка тарту мәсьәләсендә дә күп тапкырлар кисәтелдем; «Чапаев», «Цусима» әсәрләрен татарчага дошманый тәрҗемә кылынуын да белә идем, әмма, таләп ителгәнчә, нинди дә булса чара күрмәдем.

— Кызыл Йолдыз районында эшләгәндә, фирка документларын тикшерү башлангач, ВКП(б) Үзәк Комитеты директиваларын сез корткычларча үтәүгә керешкәнсез. Бу хакта бездә мәгълүматлар бар. Моның белән килешәсезме?

— ТКУда аспирантура тәмамлагач, мине Кызыл Йолдыз районына эшкә билгеләделәр. Райком секретаре урынбасары булып 1935 елга кадәр эшләдем. Фирка документларын тикшергән чакта, аңлы рәвештә Үзәк Комитет директиваларын

боздым, фирка сафларыннан чит һәм дошман элементларны чыгарып атарга дигән таләпне үтәмичә, андыйларны, райком секретаре Вәлиев белән берлектә, фиркадә саклап калдык...

«Җавап»лар шушы урында өзелә, «беркетмә» инде тиешенчә тутырылган, кул куясы гына калган иде.

Бүлмәдә тынлык урнашты. Тикшерүчеләрнең яңак сөякләре тартышып алды, тотак исә ничек дип сүз башларга белми иде булса кирәк. Каршы килсә тагын, тагын тукмаячаклар бу җанкыярлар. Кул куйса, күпме ялган монда!..

— Сез минем җавапларны үзгәртеп бетергәнсез бит...— диде тотак әкрен генә. Сугып җибәрүләреннән шүрләп, бөтен тәне җыерылды.

Тотакның сәер кыланмышы Шелудченконың күңеленә хуш килдеме, көлеп җибәрде. Аңа Крохичев кушылды.

— Вәт, анаңны кабер өстенә салып...— диде Шелудченко, өстәлгә таянып, үзе һаман көлә-көлә башын чайкады.— Безне контрның ни-нәрсә сөйләгәнен сүзгә-сүз теркәп утырырга тиеш дип уйлыйсыңмы, бүкән? И хочется, и колется, ә? Әйтәсе дә килә, әйтеп тә бетерә алмый, чөнки ул хәшәрәт! Без синең авызыңнан киләшә белән каерып алган сүзләр бу, беләсең килсә. Йә әйт, кайсы ялган монда? Нәрсә төшеп калган, нәрсә артык?

— Колхозлашу, фиркадә демократия турындагы фикерләрне үзем әйттем сезгә. Тик болар бит минем үз фикерләрем, уйлануларым, алар хакында яшермичә әйттем сезгә. Ныклы хуҗалык алып баручы крестьянның корткыч булмавын да исбатларга тырыштым. Язучылар арасында үчләшү, берберсенә яла ягарга һәвәсләр барын да күп мәртәбәләр әйттем. Алар сүзе белән ярты республиканы дошман ясап чыгарга була. Бу сүзләрдә Әхмәровның, башкаларның ни катнашы бар?

— Алтыдагы — алтмышка! — Крохичев яраткан алымы белән тотакның касыгына китереп сукты.— Бавырыңны костырам мин синең, артыңа кыздырган тимер тыгам, карышсаң. Тиз бул, кул куй диләр сиңа, елан!

Әхмәтсафа баш чайкады. Шуны гына көтеп торган кебек, Шелудченко, аны муеныннан эләктереп, югары күтәрде һәм көчсезләнеп беткән гәүдәне җан ярсуы белән идәнгә ыргытты. Типкәләргә тотынды...

Бирешмәскә теләсә дә, җан саклау өскә чыкты, бер арада:

— Кул куям...— дигәнрәк аһылдаулы авазлар ычкынды аннан.

Тикшерүчеләр инде моның ишегә күнеккәннәр, тизрәк тотакның кулына янә каләм сондылар. Әхмәтсафага монда язылганнарның әһәмияте бөтенләй юк иде, тикшерүче сузган бер кәгазьгә имза сырлый башлады...

Кул куеп бетерүгә, Шелудченко аның кулыннан зәһәр елгырлык белән каләмне тартып алды, үзен урындыктан сугып төшерде.

Ул инде үзе генә атлап барырлык хәлдә түгел иде. Ике култыгыннан ике хәрби эләктереп, камерага кертеп ташладылар. Таш идәнгә бәрелеп, Әхмәтсафа аңын җуйды.

...Күпме яткандыр, белми. Кемдер нидер сөйләнгәләп, уттай янган маңгаена юеш чүпрәк куеп маташканда аңына килде, күзләрен ачарга азапланды, әмма шушы теләкне тормышка ашыру өчен генә дә коточкыч газаплы авыртудан яңадан аңын җуя язды, башы шаулый, колакларга нәрсәдер тыгылып каткан кебек, керфекләре лакашып ябышкан, ул, ыңгырашып, кипкән иреннәрен әйләндерергә азапланып, нидер әйткәндәй булды. Теге кеше, мәхбүснең теләген чамалап алган төсле, ашыгып аның күз тирәләрен ныклап сөртте, колак тирәләрен чистартты — анда канлы лайла оешкан иде, ахры. Кинәт Әхмәтсафаның зиһене яктыра төште, хәтта үзенең таш камерада, идәндә аунавына кадәр чамалый алды. Аның хәтта күзләре йомылмаган да иде бугай, кан оешып, күрүдән мәхрүм булып кына яткан иде булса кирәк. Юеш чүпрәк үзенекен итте — күзе күпме сукмасыннар, аз-маз хәрәкәтләнә, тирә-юньне күзәтергә итә.

Камера караңгы, шулай да югарыга уелган тәрәзәдән тонык яктылык саркыла. Аның белән булашкан кешенең кыяфәте дә яманнан яман иде — сакал баскан, йөзе җимерелеп беткән, кем икәнен шайтан да таныйрлык хәлдә түгел, әмма ул хәрәкәтләнә, сөйләшә ала. Өстенә иелә төшкән шыксыз шәүлә бер ерагайган, бер якынайган сыман. Әхмәтсафа калкынмакчы иде, күкрәге чәнчүенә түзә алмыйча, аһылдап, кире идәнгә ауды. Теге кеше шулай ук аһылдый — газапланып идәнгә пәлтә җәйде, пәлтә өстенә тәгәрәтеп диярлек Әхмәтсафаны яткырган булды.

— Ничек хәлең, туганкай? — диде теге кеше, авызын сәер кыймылдатып,— ваттылармы, иблисләр? Кем син?

Бераз көттереп җавап ишетелде:

— Дәүләтъяров...— Ул инде һушына килгән иде, артык сүз ычкындырмаска тырышты.

— Кайсы Дәүләтъяров? Китап нәшриятында эшли башлаган Оренбур егетеме?

— Әйе...

— Нәшрияттан соң «Кызыл Татарстан»да редактор идең, аннан, ишетүемчә, Совнаркомда эшли башлаган идең ич син? Тыштан кергән хәбәрләргә караганда...

— Эшләргә туры килде...

— Әйе, күк түреннән сызылып үткән яшен ташы кебек хәзерге кеше. Карыйсың, бар кеше, карыйсың, юк адәм баласы. Ныклы адымнар белән югарыга үрмәләп барган җир-

дән эләктереп алалар да бавырын, җанын изеп, таш капчыкка ыргыталар. Монда һәркемнең үз хәле хәл, иректә ни барганын чамалап өлгереп булмый. Якташ булып чыктың әле син болай булгач, мә, бераз су йот.— Теге кеше Әхмәтсафаның башын күтәреп, су йоттырып азапланды. Сизелеп тора, аның үзенең дә хәле җиңел түгел, ләкин Әхмәтсафага ярдәм итәргә тырышып өтәләнә. Шушы хәл аңа көч бирде, ахры, үзен ныграк тотарга омтылыш ясады. Салкын су эчен яндырып, йөгереп үтте, башы әйләнеп, укшыйсы килде.

— Күп яттыммы монда? — диде ул, уйларын тәртипкә китерергә тырышып.

— Мине монда кертеп япканда, син саташа-саташа идәндә ауный идең инде, туганкай. Кайчан кулга алдылар соң сине?

— Егерме тугызы иде, кич, монда китерелгәндә, бәлки, инде утызы булгандыр. Төн иде. Допростан соң... берни хәтерләмим...

— Бүген, ялгышмасам, беренче декабрь инде. Өйлә үткәненә байтактан. Аунагансың аунавын, шулай да тиз аңга килдең әле. Беренче допростан соң икешәр тәүлек аңга килмәүчеләр була. Яшь кеше шул син, таза организм түзә әле ул. Безгә кыенгарак туры килә. Күп күрде башлар, яшь, шәп чаклар да үтеп бара.

— Кем соң сез? — дип сорады Әхмәтсафа, кызыксынуын җиңә алмый. Бу йомшак тавыш аңа таныш та, таныш түгел дә кебек.

— Усманов булам мин, Дәүләтъяров туган. Онытмадыңмы әле?

— Усманов? Шамил абый? — Әхмәтсафаның тавышы өзелде. Аның кулга алынуын белә иде, берчак аның язмышы хакында сүз чыккач, Әхмәров нигәдер ачулангандай итеп: «Күп сөйләшә ул Усманов, артык белдекле кылана, шуңа килеп капты»,— дигән иде. Өстәп тә куйды: «Черек күл»гә эләккән икән кеше, син аны оныт, телеңә алма, башың тыныч булыр!» Шуннан соң Әхмәтсафа бу кеше хакында да, кулга алынган башка таныш-белешләре турында да телгә алмаска тырыша иде. Әхмәровның кисәтүен исеннән чыгаруын чыгармады, тик кулга алынудан котыла алмады менә.

— Кул куйдыңмы? — диде Усманов, нидер сизенгән кебек.

— Нәрсәгә?..

— Әй Ходавәндә, ни өчен изделәр соң сине, шул алар сырлаган гаепләү кәгазьләренә диюем.— Усмановның тавышы кырысрак яңгырады.

— Куйдым... бугай.

— Бусы начар, судка кадәр бирешмәскә иде дә... Мин тартышам. Кыланып та куялар тагын, әлегә җиңә алганнары юк.— Усмановның тавышында ныклык чалынды. – Аң бул,

без «халык дошманнары» түгел! Алар дошман! Шуны аңласаң, кем белән эш йөрткәнеңне төшенсәң, җиңелрәк була ул.

— Ни өчен бу газаплар безгә? — диде Әхмәтсафа ачынып.— Безнең ни гаебебез бар?

— Гаепме? Бар анысы. Без революциягә сукырларча ышандык. Без тарихның табигый агышына каршы гамәл кылуда турыдан-туры катнаштык, кан, үле гәүдәләр өстендә яңача тормыш төзергә маташтык. Бу иң зур ахмаклык булган. Мин моны соңрак аңладым, таш капчыкка эләккәч, уйларга вакыт бар менә. Гомернең кыйналудан калган өлеше уйланып кына үтә. Ата-бабаларыбызның йолаларына төкереп, үзебезчә әхлак әвәләдек, сәясәт укмаштырдык, денсез-имансыз кавемгә әйләндек. Шушы хәлдә үзебезне гаепсез итеп, акланып маташу зур хата, Дәүләтъяров. Болар барысы да безнең акыл, безнең йөрәк белән эшләнде. Без үстергән үсентеләр агулы җимеш бирделәр. Аларны без ашамыйча, кем ашасын?

Әмма озаклап сөйләшергә-аңлашырга форсат булмады, ишек шалтырап ачылды, каты тавыш ишетелде:

— Усманов, допроска!

— Йә, хуш, якташ. Бу, изеп чыгаргач, һушка килгәнче ята торган камера инде... Сорау алу алдыннан тотакларны шушында кертеп торалар. Керүеңә, синең кебек аңсыз яткан гәүдәгә тап буласың. Кешенең рухын сындыру өчен ни генә кыланмыйлар инде.

Хәрбинең сүгенгән тавышы яңгырады:

— Тиз бул! Сөйләшмә, тегендә баргач сайрарсың...

Усмановның авыр адымнар белән чыгып китүен Дәүләтъяров шомланып карап калды.

...Беренче сорау алганнан соң, аны озак чакырмый тордылар тикшерүче янына. Гел бер кешелек камерада ятты. Ара-тирә аның янына тукмап ташланган мәхбүсләрне кертеп ташлыйлар, тегеләр, аңнарына килеп, бераз сөйләшеп алырга өлгерми, тагын алып чыгып китәләр, шулай көн артыннан көн үтә. Бер тоткыннан ишетте, Шамил Усмановны тикшерүче бүлмәсендә кыйнап үтергәннәр, әмма ул бер кәгазьгә дә кул куймаган икән... Моны ишеткәч, Әхмәтсафаның күңелендә Усманов әйткән сүзләр яңгырады:

— Судка кадәр түзеп булса...

...Инде «оныттылар» дисә, юк, һич тә алай түгел икән. Декабрьнең егерме бише көнне кабат сорау алырга чакырдылар.

Крохичев күп сөйләшеп тормады. Сакал-мыек баскан, йөз чалымнары шактый үзгәргән тоткынга җирәнгеч караш ташлап алды да аның алдына кәгазь китереп салды:

— Шушыңа кул куй, и эшең бетте.

Дәүләтъяров, күзен кискән ут яктысыннан читкә боры-

лып, язылганнарны укый башлады. Китап нәшриятында эшләүче шактый кешене «халык дошманы» итеп күрсәтү, Авзал Шамов, Нур Баян, Мирсәй Әмир кебек иректә калган язучыларга яла ягуга нигезләнгән бу кәгазьне Әхмәтсафа ачу белән Крохичев алдына этәрә төште.

— Мин бу кешеләрне яхшы беләм. Алар ничек дошман булсыннар? Кул куюдан баш тартам.

Крохичевның йөзенә кара йөгерде. Шулчак телефон шылтырады. Тикшерүче сикереп торды, аннан нидер исенә төшкәндәй, кире урынына утырды.

— Безгә синең кул куюың кирәкми дә, контр! Бәхетең, синең белән маташырга вакыт юк, Михайлов чакыра.— Ул ишек янында таптанган хәрбигә җикеренде: — Гатинга эндәш, ныклап ярыгыз да бу кабихне, камерага кертеп ташлагыз!

## XIV

Дөрес әйткән Усманов. Кыйналудан калган вакыт уйланып үтә... Өйгә кайтарырлар дигән өмет инде әллә кайчан буш куык сыман сүнде, бетте. Кулга алынучылар ишәя, камераларда урын җитми, дүрт-биш кеше сыяр камерага, кайчак, иллешәр кешене кертеп ябалар. Кешеләр кыйналу җәфаларыннан үткәннәр, авызларын үлчәп ачалар, бер-берсенә ышанмыйлар, шулай да әгәр бер камерада булып, яки бер «эш»кә бәйләнгәннәр, ничектер очрашып, сүз куеша алсалар, каршы сорау алуда аларга нинди дә гаеп тагылса, шуңа «әйе, шулай» дип җавап биреп, кыйналудан сакланып калалар. Каршы килсәләр, җанкыярлар котырып кыйнап, барыбер үз дигәннәрен эшлиләр.

Аны ялгыз камерадан гомуми тотаклар янына керткәнгә, атна үтмәде, медицина тикшерүе дип аталган нәрсәгә алып киттеләр. Яңа ел алдыннан иде бу.

Ишекне ачып, табиб бүлмәсенә керсә, башын кыек салып, нидер язып утырган табибәне күреп, һушсыз калды. Керүчегә күз дә салмый утырган саргылт төс кунган ак халатлы, боек йөзле табибә — Заһидә иде...

Теге чакларда балкып, янып торган, бер карасаң, беркатлыланып һәрнәрсәгә гаҗәпләнеп туймаган кызыйга, икенче баксаң, мизгел эчендә үзгәреп, әллә нинди серле гүзәллек биләп алучан аксыл йөзенә үпкәләү галәмәте сирпелеп китүчән туташка һич тә охшамаган иде төрмә хастаханәсендә Әхмәтсафаны битараф каршы алган Заһидә. Йөзенә сары йөгергән, күз төпләре зәңгәрләнеп эчкә баткан, иреннәренә күгәрек кунган. Кайчандыр нур чәчеп торган күзләре уңып беткән төсле, карашы ышанычсыз һәм салкын.

Табибә сакчы озатуында килеп кергән базык гәүдәле сакал-мыек баскан тотакның Әхмәтсафа икәнен беренче караштa танып та бетермәде кебек. Ишек янында кисәк туктaлып калган мәхбүскә күтәрелеп карамыйча, өстәл янындагы идәнгә ныклап беркетелгән тимер урындыкка күрсәтте:

— Утырыгыз...

Нинди серле көч тарткандыр, Әхмәтсафа табибәгә якынрак елышасы килде. Моны Зәһидә дә сизенде кебек.

Алдында яткан кәгазьгә нидер язарга хәзерләнгән җиреннән кисәк тотакка күтәрелеп карады, аннан берни булмагандай, ачык тавыш белән:

— Фамилиягез? — диде.

— Дәүләтъяров...— Әхмәтсафаның тавышы калтыранып чыкты. Танымый, ахры... Әллә танымаган булып кыланамы? «Бу — мин бит, Әхмәтсафа, синең яшьлек дустың!» — дип ачыргаланып кычкырып җибәрәсе килә дә бит, ярамый. Төрмә кануннары башка, тәртип икенче. Монда юктан бар ясыйлар, барны юк итәләр.

Тотакның фамилиясен ишеткәч, Зәһидәнең сары сарган йөзе тартышып куйды. Әмма сер бирмәде, салкын тавыш белән:

— Билгә кадәр чишенегез,— диде. Үзе вак-төяк нәрсәләр салынган калай банкадан нидер эзләгәндәй кылана башлады.

Әхмәтсафа авырлык белән генә, аһылдап, күлмәк төймәләрен ычкындырды, бераз тын алганнан соң янә чишенүен дәвам итте. Аның нинди тәмуг газапларын татуын аңлап алган Зәһидәнең күзенә яшь тыгылды, тик моны беркемгә дә сиздермәскә кирәк иде, ул шуңа күрә урыныннан кузгалып түрдән урап килде.

Гадәттә, монда китерелгән тотакларны озаклап-төпченеп тикшерүләрне яратмыйлар НКВД карчыгалары, тотак кыйнаулардан соң имгәнеп аягына баса алмаса гына, төрмә хастаханәсенә илтеп ташлыйлар. Зәһидәнең бурычы үз аягы белән килеп кергән тотакның тән температурасын үлчәп маташкан булу, кан басымын тикшерү дә, беркетмәгә «эш өчен куллануга яраклы» дигән тамга салу. Бик сирәк очракта гына, тотакның хәле яманнан-яман булганда гына аны лазаретка җибәрергә рөхсәт итә ул үз инициативасы белән, һәм бу адымы өчен аңа хәрбиләрдән кем алдында булса да җавап тотарга туры килә. «Эш өчен куллануга яраклы» дигән тамга ике төрле юлны күрсәтә, берсе — тотакны алга табан да җәзалый-җәзалый сорау алуны дәвам итүне аңлатса, икенчесе — төрмәгә алып китеп, төрле эшләргә йөртә башларга мөмкин дигән сүз иде.

Зәһидә Әхмәтсафаның тимгел-тимгел канга каткан, әмма тән җылысы сакланган күлмәген кулыннан алып урындык

артына ташлады да, аны бүлмәнең түренәрәк, тәрәзәдән төшкән сүрән яктыга әйдәде, сакчының табибәнең бу кыланышын артыкка санап, түшәмнән нидер «эзләп» торуыннан файдаланып (сакчының монда беренче генә килүе түгел, бу тотакка караганда ныграк «ватылган»нарын да градусник белән тән температурасын үлчәп кенә җибәрәләр, кая ул ныклап тикшереп тору, киресенчә булса, табибларның үзләрен саботажник, корткыч дип, камерага кертеп ябарга күп сорамыйлар, андый хәлләр күп инде. Сакчы аларын да белә, шуңа күрә түземсезләнгән кыяфәттә күзләре белән бүлмәне айкаган булып вакыт үткәрергә тырыша), Зәһидә пышылдап өлгерде:

— Таныдым… Эндәшмә…

Әхмәтсафаның кыйналудан шешенеп беткән, зәңгәрсу-сарыланып торган тәнен, кумаклар яргалаган, һич тә төзәлергә ашыкмаган беләкләрен күреп, башы әйләнеп китте. Аумас өчен, нык кына Әхмәтсафаның беләгенә тотынды, тотак, йөзен чытып, аһ дип куйды.

Зәһидә, үзен кулга алып, дорфа тавыш белән:

— Түз, чебен тимәс чер итәр нәрсә! — дигән булды. Ясалма дорфалык астында аның хәлен җиңеләйтү өчен ни дә булса кылырга омтылыш ятканын сизгән Әхмәтсафаның күңеле тулып, тамагына төер утырды. Зәһидәдән монысын да яшереп булмады. Куллары дерелдәвеннән табибәнең дә нинди хисләр өермәсендә калуын аңларга була иде. Әхмәтсафа нидер әйтергә җыенган иде, шуны гына көткәндәй, Зәһидә, иреннәрен нык кысып, аның күзләренә карап, башын чайкап куйды. «Эндәшмә, барысын да күрәм, аңлыйм, аз гына булса да хәлеңне җиңеләйтү өчен бер-бер чара табарга тырышам. Берүк артыгын гына ычкындырып ташлама, мине белмәгән булып кылан», дигәнне аңлата иде Зәһидәнең бу кисәтүле карашы…

— Киенегез, — диде Зәһидә, авыр сулап һәм сакчыга әмер биргән төс белән, — лазаретка озатырга туры килә, — диде. Аның тавышы ныклы, чигенергә урын калмаслык иде. — Дәваламыйча булмый. Күкрәк капкачы урыныннан купкан. Шуннан соң гына комиссия каравына җибәрергә мөмкин.

Лазаретка өйләдән соң кертеп яптылар, бер стакан җылымса чәй биргәннәр иде, шуңа хушланып, кечке ашка кадәр йоклап алды, тоткыннар үзара чыш-пыш сөйләшәләр, ара-тирә колакка уникенче декабрьдә үткән сайлаулар, алдагы елда, гыйнвар аенда булачак СССР Югары Советының тәүге сессиясе хакындагы сүзләр чалынып ала. Барысы, шул исәптән Әхмәтсафа да, бу вакыйганы ашкынып көтә. Сессия эшендә илдәге хәл ныклап тикшерелер, депутатлар төрмәгә ялгыш килеп эләккән бер гаепсез партия-совет органнарында эшләүче элекке хезмәттәшләрен дә исләренә төшерерләр,

һич булмаса, амнистия игълан ителер, күпләре ирекккә чыгар да, иптәш Сталинга, партия, Совет иленә никадәр тугры икәнен эш белән расларга мөмкинлек туар дип өметләнәләр. Партия кая җибәрсә, шунда барырга риза һәммәсе. Төрмәдән, НКВД сагы астыннан гына котылсыннар, раслаячаклар әле алар үзләрен ни-нәрсәгә сәләтле икәнлекләрен!

Әхмәтсафа, үз хәлен уйлап, хәсрәтле көлемсерәп куйды. «Бичаралар, иректә без нәрсәгә яраклы булырбыз икән соң? Ничек газаплаганнарын искә дә аласы килми, бу кадәрерткычлыкны, вәхшилекне сөйләп-аңлатып кына бетерерлек түгел. Тәндә исән җир юк, сытылган күкәйлек шешеп тишелде, бот төбеннән туктаусыз үлек-эрен ага, монда эләккән башка тотакларның хәле тагын да яманрак, амнистия-мазар булып, төрмә капкалары аша үз аякларыбыз белән чыга алсак ярый да... Өмет аз шул. Ярты көн үтте, бер авыру янына бер табибның килеп караганы юк, күрәләтә үлем көтеп яту инде бу. Шулай да күңел түрендә нәрсәгәдер ышану бар, әле рухлары бөтенләй үк сынып бетмәгән үзләренең. Әллә берберсе алдында шулай кыланаламы? Кысан камерада илле-алтмыш кешене кертеп япкач та, телләре ачылып китсә, һәркем үзенең «дошман» булмавын дәлилләп сөйләп калырга тырыша, чөнки беләләр, арада ике-өч сатлык бар, камерада кем нәрсә сөйли, алар түкми-чәчми тиешле урынга җиткереп торалар. Монда да шул ук тәртип бугай.

Уйлар ихтыярына бирелеп, янына Заһидә килеп утырганын сизми дә калды. Аны күргәч, елмайгандай итте.

— Шундый хәлләр, Заһидә... Кем уйлаган...

Заһидә бу сүзләргә игътибар итмәстән, пышылдап сорау яудырырга тотынды:

— Кайчан? Ни өчен?

— Айга якын ятам. Эштән алып, китереп яптылар. «Дошман» диләр...

— Өмет бармы соң? Чыгарга дим...

— Чыгарга юк, чыдарга дисәң генә инде... Бөтен өмет судка кадәр исән калу. Совет мәхкәмәсе чын дөресен ачыклар дип уйлыйм. Шамил Усмановның киңәшен тотам — судка кадәр теге дөньяга китми түзсәм, әлбәттә... Бар юаныч шул. Кызык бит.

Заһидәнең керфекләре дымланды.

— Шамил Усманов дисең инде, алайса...

— Кара әле, Заһидә, аның турында төрле сүзләр йөри. Исән түгел дә, диләр. Әхмәтсафа «кыйнап үтерделәр» димәкче иде, күрше ятакта ятучы тоткынның сәер карашын сизеп, сүзен башкачарак төгәлләде. Башына шаулап кан йөгерде. Таныш, бу кеше аңа бик тә таныш. Минзәләдә чакта юк-бар бәйләнүләре белән теңкәгә тигән Шәмтиев бит, каһәрең...

Әхмәтсафаның йөзе үзгәреп китүен сизгән Заһидә, аптырап калды.

— Ни булды, төсең китте? — диде ул, куркынган тавыш белән.

— Тыңлыйлар...— диде Әхмәтсафа пышылдап, янәшәдә яткан авыруга ым какты.— Хуш, сау бул, Заһидә, минем аркада яна күрмә.

— Янасы янды инде,— диде Заһидә,— бер җыелышта тормыш авырлыклары аркасында бала төшерүче хатыннарның күбәюе хакында сөйләп ташлаган идем, шул ук төнне төрмәгә китереп яптылар. Мондагы хәлләрне күрдем инде...

Әхмәтсафаның һаман-һаман күрше ятактагы авыруга күз ташлавына түзми, Заһидә ачуланып алды:

— Курыкма, аның күп яшәрлеге калмаган... Бөерен эштән чыгарганнар. Көннәре санаулы.

— Шулай да саграк бул, Заһидә. Син һаман элеккечә, турыдан ярасың.

— Бер гаебем дә юк ич...— Заһидәнең кинәт күзләре кабынып китте.— Беләсеңме, Әхмәтсафа, монда килеп эләгүемне белгәч, Фатыйх Сәгыйтов минем арттан шактый чапкан бит. Башта ишеттем, аннан үзеннән күчтәнәч, хат алдым. Сине йолып алмыйча туктамыйм, дигән.

— Әйбәт... Фатыйхны аңлавы кыен, көйлерәк кеше булды инде ул.

— Шулай да ярдәме тиде, камерада корчаңгылап ятканчы, төрмә хастаханәсенә җибәрделәр эшкә. Ярым ректә йөргән булам. Кара әле, Әхмәтсафа, гаиләңә хәбәр чыгара алганың бармы? Хәлеңне беләләрме?

— Юктыр, алдан сөйләшү буенча хатыным бу тирәгә аяк та басарга тиеш түгел иде. Киңәшемне тота торгандыр, акыллы хатын ул,— диде Әхмәтсафа, керфегенә яшь бөртекләре эленүен сизеп, күзләрен кул аркасы белән сыпырып алды.

— Ничек инде «алдан сөйләшү буенча»?!

— Нәрсәсен аңламыйсың, рәттән кулга алганда, мине генә читтә калдырмасларын аңлый идем, шуңа күрә алдан ук әйтәсен әйтеп куйдым... Балалар хакына, дидем...

— Сәгыйтовка хәбәр бирсәм?

— Зинһар өчен, аны да безнең эшкә китереп бәйләмә. Сабакташлардан кем дә булса исән-имин калсын.

— Бигрәк өметсез сөйләшәсең син.

— Өмет әйбәт нәрсә ул, Заһидә, әмма чынбарлык чабудан тотып тора, чынбарлык шулкадәр аяусыз. Ул — өметне миңа, мине өметкә бер адым да якын җибәрми. Өмет белән ерактан гына сөйләшәбез.

— Оста да инде телгә үзең. Язучы гына буласың калган.

— Язучы булсам да, язмыштан качып булмас иде, күбесе

монда бит аларның да. Әйе... Шамил Усманов турында сораган идем. Җавап бирмәдең...

— Ул инде күптән вафат. Декабрь башында ук.

— Ничек вафат. Кыйнап үтерүләре хакмы?

— Башына җиттеләр... Ходай каргышы төшәр микән аларга, Әхмәтсафа?

— Төшүен төшәр дә... Без генә күрмәбез.

Заһидә китәргә кузгалды.

— Йә, дустым, бирешмә. Әле иртәгә дә керермен. Яшәргә тырыш,— дип, Әхмәтсафаның агарган чәчләрен сыйпап алды да, башка авыруларга күз салмаска тырышып, рәт араларыннан кыскарак юлны сайлап, ишек янына атлады.

Төн уртасында янәшәдә нидер мыштырдавын ишетеп, Әхмәтсафа уянып китте. Сүрән ут яктысында Шәмтиевнең ишек төбендә утырган сакчы ягына табан атлавын күреп алды. Шәмтиев сакчының колагына иелеп нидер әйтте, сакчы, башын селкеп, риза икәнлеген аңлатты. Ул да булмады, күрәсең, сакчының хәбәр бирү җае бардыр, ишектән ак халатлы бер кеше кереп, Шәмтиевне ияртеп алып чыгып китте.

Шәмтиев таң алдыннан гына кайтып егылды ятагына. Иртән исә, хәле начарланып, ыңгыраша, саташа башлады, кемнедер чакыра, кемнедер куа. Әхмәтсафа түзмәде, сакчыга мөрәҗәгать итте:

— Авыру янына табиб чакырыгыз әле, хәле мөшкел...

Сакчы, авызын чалшайтып, җавап кайтарды:

— Төне буе кызлар янында йөрде бит.— Көлгән булды, кисәк авызын җыеп, киңәш иткән тавыш белән әйтеп салды:— Сиңа, контр, аның өчен бик үк өтәләнмәсәң дә була... Кайберәүләрне бүтәкәләре-ниләре белән сатты ул төнлә.— Сакчы, күзен чепиләндереп, Әхмәтсафага озак кына карап торды.

Әхмәтсафаның аркасына суык үрмәләде.

Шәмтиев газапланып җан бирде...

Әхмәтсафа көнозын Заһидәне көтсә дә, ак халатлы табибә ул көнне дә, икенче көнне дә күренмәде. Аны Шәмтиев әләге белән яңадан камерага илтеп тыкканнар иде булса кирәк. Берничә көннән соң аны янәдән медицина комиссиясе тикшерде. Комиссия — дәүләт куркынычсызлыгы идарәсенең сигезенче бүлек башлыгы (үзе медицина комиссиясе җитәкчесе дә иде) һәм бер табиб — ир кеше Дәүләтъяровны «эшкә яраклы» дип тапты.

Шуннан соң аны гаепләү карарына кул куярга чакырдылар. Крохичев төксе генә аның алдына карар язылган кәгазьне китереп салды һәм алдан ук әйтеп куйды:

— Сузмыйча гына кул куй. Башны әйләндерергә уйласаң, чамала!

Әхмәтсафа укый башлады.

К а р а р

*Казан шәһәре, 1938 елның 15 гыйнвары.*

Мин, Татарстан республикасы Эчке эшләр халык комиссариаты дәүләт куркынычсызлыгы идарәсенең дүртенче бүлек башлыгы урынбасары өлкән лейтенант Крохичев, җинаять кодексының 58–102.1 һәм 58–11 маддәсе буенча гаепләнүче Дәүләтъяров Әхмәтсафаның 23389 санлы тикшерү эшен караганнан соң,

т а п т ы м:

Дәүләтъяров Ә.М. үз алдына совет хакимлеген бәреп төшерүне, ВКП(б) һәм совет хөкүмәте җитәкчелегенә карата террористик актлар булдыруны максат итеп куйган. Татарстандагы уңтроцкийчы милләтчел контрреволюцион оешмада катнашкан.

Дәүләтъяров, шушы советка каршы контрреволюцион оешмада катнашучы буларак, контрреволюцион террористик карашларны хуплаган, шуларны искә алып,

к а р а р  ч ы г а р д ы м:

Гаепләнгән маддәләргә өстәп, Дәүләтъяровны гаепләү эшенә РСФСР җинаятьләр кодексының 17–58–8, 58–12, 58–7 маддәләрен дә кушарга...»

Крохичев тотакка күз салып алды да, аның үз каршысында бөкрәя төшеп керфек тә селкетми тыңлап торуына канәгатьләнеп, гадәти бер нәрсә кылгандай, карар хакында прокуратурага хәбәр итү тиешлеге турында укып чыкты.

— Тагын кул куярга туры килер... — диде ул, ниндидер мөһим җиңү яулаган кыяфәттә. Ул тантана итә иде.

Әхмәтсафа күңелендә уйнаган өермәне сиздермәскә тырышты. Еларга дисә, ул елый алмый, бәгыре таш-тимердәй каткан, җанын талкыган уйларны читкә куарга өйрәнде, карашы төссез һәм салкын иде. Бер генә мизгелгә өстенә шаулап торган кайнар су койган сыман бер халәт кичерде дә, барысы да тынып калды сыман. Каршында торган НКВД кешесе тизләнеш алып каядыр еракка китеп югалды, бүлмәнең диварлары вәч-вәрәмәч тузып, ботарланып ташландылар, өстәл-урындыклар җил себереп киттеме, юкка чыктылар, үзе исә таушалып, ертылып беткән кәчтүненнән шуып кына чыкты да күккә ашты. Гаҗәеп рәхәт иде аңа, «Черек күл»гә килеп эләккәннән бирле мондый җиңеллек кичергәне булмады да. Күңелен биләп торган барлык шик-шөбһәләр җуелды, дөнья чайкалып зырлап әйләнде дә бөтенесе үз урынына кире кайтты. Ул тимердәй каткан җаныннан иңгән салкынга бөрешеп тора, каршысында тантана итүче Крохичев...

Аннан ни таләп ителгәнен исеннән чыгарырга өлгермәгән иде әле. Көтелмәгәнчә, елмаеп, кире сорау бирде:

— Кул куярга дисезме?..

Моны көтмәгән Крохичев каударланып җавап кайтарды:

— Әйе, нит инде... Кул куясың да, син — азат.

— Ничек азат?..

—Төрмәгә китәсең... Азатлык көтмә, контр. Барып чыктың инде.

Әхмәтсафа эндәшмәде. Ул язмышының ахырына җитеп килүен белә иде инде, ялын, ялвар, җәлладлардан гомерне озайтып булмаячак, алар хәл иткәннәр, алар — меңнәрнең Газраиле бүген. Бетте, барысы да тәмам... Менә шушы чакта күзеннән яшь саркыды. Ул ашыгып өстәл өстендә яткан кәгазьгә кул куйды да йөзен читкә борды һәм тетрәнеп китте: карашы төшкән почмак яктан еректан-ерактан томан аша аңа Рабига карап тора иде. Йөзендә аптырау галәмәте, чарасызлык. Арык куллары белән янәшә басып торган үсеп килүче ике улын кысып тоткан да, аңа инәлгән. «Нишләдең син, нишләдең?.. Кул куя күрмә, анда язылганнар барысы да ялган, бер генә дөрес сүз дә юк, яла ягып башыңны бетермәкче булалар. Ә без?..»

Бу тавыш фәкать Рабиганыкы гына була ала. Кайдадыр еракта әнә ул өзгәләнә, ялган гаепләүләргә кул куймаска өнди сыман. Аны Рабига йолып калырга итә, малайларны бер кулы белән кочып, икенче кулы белән Әхмәтсафага үрелә. Бар дөнья яктырып китте, йа Хода, тотак булып күргән-кичергәннәре төш кенә икән бит. Гаҗәп, барысы да үз урынында, барысы да элеккечә икән лә! Сакмар өсләп кояш күтәрелә, бакчадагы алмагачлар шау чәчәктә. Агач арасында нидер көйләп әткәсе йөри, әнә аның тирәсендә яшь балалар пәйда булды, Марат белән Марлес, ахры. Әнисе кай арада кулыннан ычкындырган соң аларны? Тиктормас малайлар, тагын кайларга китеп югалырлар, эзләп табып булмый хәл бетә бит аларны!.. Су өстендә елык-елык кояш нурлары йөгерешә, каршы яктагы таллар, суга кадәр башларын иеп, агымсу белән уйныйлар, үзләре генә белгән серләрен ярсып аккан суга агызып, моңаялар кебек. Кошлар җырыннан мөкиббән киткән җикән камышлар, шушы өзелмәс көй уңаена әкрен генә чайкалып, уйга батып утыралар. Табигать серле сандык бит ул, аның эченә яшерелгән серләрне кем генә ачып, аңлап бетерер дисең!

...Күз аллары караңгыланып торган Әхмәтсафаны җилкәсеннән кемдер умырып тотты, нык кына эндәште:

— Концерт тәмам, Дәүләтъяров. Сакчы, тотакны камерага алып китегез!

Хыялдан арындырып, чынбарлыкка кайтарган тикшерүчегә Әхмәтсафа нидер әйтәсе килеп, авыз ачкан иде, кире уйлап, сүзсез генә ишеккә табан кузгалды...

# ЭПИЛОГ

Әсәргә нокта куяр вакыт җитте.

ТАССР Эчке эшләр халык комиссары («халык» дигән сүзне мин монда зур бер әрнү вә хәсрәт хисләре кичереп язам) Василий Михайлов кул куйган 1639 нчы ордер нигезендә кулга алынган Дәүләтъяров Әхмәтсафа Мостафа улына карата РСФСР җинаять кодексының 17–58–1, 58–2, 58–7 статьялары буенча гаепләү «эше» 1937 елның егерме тугызынчы ноябрендә ачылган һәм тикшерү эшләре беткәнгә саналып, 1938 елның унбишенче гыйнварында ябылган.

3389 нчы «Дело» башкаларга караганда артык калын булмаса да, анда шактый гыйбрәтле документлар саклана. «Халык дошманы» буларак кулга алынган, заманында Татарстанда иң зур постларның берсен биләгән Әхмәтсафа Дәүләтъяров «эше» буенча тикшерүгә тартылган кешеләр байтак. Аларның үз-үзләренә, хезмәттәшләренә, хәтта бөтенләй белмәгән кешеләргә дә яла яккан, гаепләгән күрсәтмәләрен, мәгълүматларын, шаһитлык кылуларын раслаган дистәләрчә документларын күрсәтә алган булыр идем. Әмма инде «үзгәртеп кору» дип аталган дәвер килеп, НКВД, КГБ архивлары ишекләре ачылгач, матбугатта миңа да, сезнең кебек үк, бу темага кагылышлы күп язмалар укырга насыйп булды. Совет режимының бер гаепсез кешеләрдән «террорист»-лар, «корткыч»лар ясау ысуллары хакында Булат Солтанбәков, Алексей Литвин, Индус Таһиров, Рәмзи Вәлиев һәм башка хакыйкатьне дөньяга чыгаруда армый-талмый эшләгән фидакарь галимнәребез хезмәтләре аша да беләбез. Мин дә әсәрне язган чакта бу хезмәтләрне җентекләп өйрәндем. Оренбур, Казан архивларында эшләдем, кызыклы истәлекләргә тап булдым, ул чорның вакытлы матбугатын җентекләп тикшердем, тарих төпкелләрен актардым.

Минем өчен иң әһәмиятлесе, Әхмәтсафа Дәүләтъяровның олы улы Марат аганың булышлыгы белән Татарстан КГБсы архивында булып, Дәүләтъяров Әхмәтсафа улына кагылышлы «Дело» белән таныштым. Хәтта архив хезмәткәре Ә.Сәгыйтованың ярдәме белән ул чакта «халык дошманы» дип кулга алынганнарны ябып тоткан камераларны да үз күзем белән күрдем. Шул кечкенә камераларда, мичкәдәге балык кебек дыңгычлап тутырылган тотакларны күз алдына китереп, йөрәк сулык-сулык тибә, тамакка төер килеп утыра.

Гаепсез көйгә үзләрен гаепләгән кәгазьгә кул куйганнары, башкаларны гаепләп шаһитлык кылганнары өчен гөнаһлымы соң бу тотаклар? Инде язмыш аларга бер мәртәбә коточкыч гаделсезлек, аяусызлык күрсәткән, без кабат аларны гаепләп, үз өстебезгә гөнаһ алмыйк та, аларга карата ка-

бат аяусыз булмыйк. НКВДның җәза конвейерына эләккән һәм барысын да үзләре күргән, кичергән кешеләр генә ни өчен ялган язып тутырылган кәгазьләргә кул куйганын чамалыйдыр. Ходай кичерсен аларны, Ходай хөкем итсен, безнең ул эшкә хакыбыз юктыр. Кул куймыйча, подвалларда кыйналып үлүчеләр дә булган, андыйлар сирәк...

«Халык дошманнары»н фаш итүдә социалистик ярыш ачып, разнарядка белән баш исәбен генә тутыру өчен кулга алып, җәзага тартуны аңлап та булмый, ул бернинди мантыйкка да сыймый. Анысы шулай. Ләкин утыз җиденче ел шаукымы бездән еракмы? Утыз җиденче елларның кара болытлары безнең баш өстендә хәзер дә әйләнеп-тулганып йөрмиме? Кем ачык кына юк дип җавап бирә ала? Уйласаң, җаннар өшеп куя.

Инде билгеле булганча, 1938 елның гыйнварында СССР Югары Советы сессиясе барган көннәрдә Татарстаннан сайланган Югары Совет депутатлары (Әхмәтсафа Дәүләтъяров урынына Чистай сайлау округыннан Милләтләр Советына җир эшләре халык комиссариатыннан Авзалетдинов сайлана) Алемасов белән Михайлов Николай Ежов янында булалар. Ежов, хисапны тыңлаганнан соң, Татарстанда «халык дошманнары»н фаш итү буенча башкарылган «эш»не хуплый. Тегеләр, мактаудан иләсләнеп китеп, «халык дошманнары» Татарстанда бихисап, разнарядканы арттыру кирәк дип ялына башлыйлар. Ежов моңа кадәр бирелгән ике-өч мең «халык дошманы»на разнарядканы сигез меңгә кадәр «күтәрергә» рөхсәт бирә. Нормаль акыллы кешеләрме болар? Алар кылган шушы бер гамәл генә дә акылга сыямы?

...Ежовның урынбасары Фриновский янында булгач, Михайлов үзенең урынбасары Шелудченкога болай дип хәбәр итә:« Фриновский бу бәндәләргә каршы килми, ахыр чиктә, махсус сессия аша үткәрергә кирәк». Ягъни беркемне аямаска, тоткыннарга карата НКВД хезмәткәрләренең «акылларыннан», көчләреннән килгән барлык җәза ысулларын кулланырга, мөмкин дип тапканның барысын да эшләргә рөхсәт алына. Ни өчен шәхескә карата бу кадәр ерткычлык? Карьера өчен, түшкә орден тагар өчен, ди... Һәм... тагын. Тагын шул ук сорау — ни өчен бу ерткычлык кирәк булды совет хакимиятенә? Гафу итегез, инде зиһен җитми... Ул чор турында, Сталин, башка җитәкчеләр хакында калын-калын китаплар язган авторлар да газаплана-газаплана шушы сорауга җавап эзлиләр, үзләренчә нәтиҗәләр ясыйлар, ләкин мантыйкка сыешлы җавап кына таба алмыйлар. Табып та булмаячак! Чөнки әлеге сәясәт, мондый җинаятьчел хакимият мантыйкка каршы, яшәеш-тормыш агышына, табигатькә каршы.

1938 елның унберенче мартында Михайлов Әхмәтсафа

Дәүләтъяров эше буенча әвәләнгән «Обвинительное заключение»гә кул куя. Әле сигезенче мартта Баш Хәрби Прокуратура прокуроры икенче ранглы хәрби юрист Вышинский раслаган һәм кем тарафыннан, кайчан язылуы да билгесез («Обвинительное заключение составлено в г.Казани» дип кенә язып куелган һәм март аенда булса кирәк) «гаепләү»дә нәрсәләр язылуын күздән кичерсәң, янә бер мәртәбә биһуш булып торасың.

Обвинительное заключение
(по делу 3389)
По обвинению

Давлетъярова Ахмет-Сафа Мустафовича по ст. 58–2, 58–7, 58–8 и 58–11 УК РСФСР.

УГБ НКВД Татарии вскрыта и ликвидирована антипартийная право-троцкистская организация, активно действующая в блоке с национальной пантюркистской организацией, под руководством московского правотроцкистского террористического центра.

Как установлено следствием, одним из активных участников этого контрреволюционного блока является обвиняемый по настоящему делу Давлетъяров А. М., который:

а) в 1928–1932 г. во время учебы в ТКУ высказывал несогласие с политикой партии по национальному вопросу;

(л. д. 13 н\о)

б) работая в последующее время в Татгосиздате, установил связь с активными участниками антисоветской пантюркистсткой национальной организации, Ахмеровым (арестован), и им же в 1936 г. был завербован в организацию;

(л. д. 11, 13, 52–53, 56, 55–58)

в) в 1936–1937 г., работая в Татгосиздате, проводил вредительскую подрывную работу на идеологическом фронте;

(л. д. 15, 16, 24–29, 33–34, 35–38, 39, 41–42, 46–47, 54, 55)

г) в 1937 году, являясь переводчиком и соредактором перевода книги товарища Сталина «Вопросы ленинизма», извращал последнюю в контрреволюционном духе;

( л. д. 15, 46 н\о)

д) проводил вербовку новых лиц в антисоветскую националистическую организацию (завербовал Мирзаханова, Файзуллина и Ишеева);

(л. д. 30)

е) стоял на позициях террора против руководителей ВКП(б) и соввласти и был осведомлен о ведущейся подготовке к совершению террористических актов;

(л. д. 14 н\о, 59, 60)

В своей преступной деятельности виновным себя признал

полностью и изобличается показаниями соучастников: Лепа, Нежметдинова, Байчурина, Рахматуллина, Мухаметзянова, Чукальского, Сафарова, Башкирова, Абрамова на очной ставке с Мирзахановым.

На основании вышеизложенного:

Давлетъярова Ахмет-Сафа Мустафовича — 1905 г. р., татарин, гражданин СССР, уроженец деревни Каргали Сакмарского района Оренбургской области, сын торговца, образование высшее, служащий, бывший член ВКП(б) с 1925 по 1937 — исключен за антисоветчину, до ареста председатель СНК ТАССР

обвиняется в том, что:

а) является одним из активных участников антисоветской правотроцкистской национальной террористической организации, совершившей 1 декабря 1934 года злодейское убийство С. М. Кирова и подготовившей террористические акты на других руководителей партии и правительства, вел организованную борьбу за вооруженное свержение советской власти и реставрацию капитализма;

б) проводил вредительскую подрывную работу на культурно-идеологическом фронте, в особенности по линии Татгосиздата, виновен в преступлениях, предусмотренных ст. 58–2, 58–7, 58–8 и 58–11 УК РСФСР.

Настоящее дело в порядке закона от 1.12.1934 г. подлежит рассмотрению Военной Коллегией Верховного Суда Союза ССР.

Обвинительное заключение составлено в г. Казани.

...Аларны 1938 елның сигезенче-тугызынчы маенда, язның иң матур көннәрендә хөкем итәләр. Суд (хөкем яки мәхкәмә дип язасым килми) көтеп ятуның никадәр авыр, ялыктыргыч, рухи җәза икәнен башыннан кичкән кешеләр генә беләдер. Билгеле булганча, бу көнне Казанда «халык дошманнары»на «зур хөкем» көне үткәрелә. Барлыгы йөз туксан ике кешегә хөкем карары чыгарыла. Алар арасында Лепа, Абрамов, Байчурин, Дәүләтъяров кебек республиканың иң зур җитәкчеләре дә, Ләбиб Гыйльми, Галим Мөхәмитшин, Сөббух Рафиков кебек япь-яшь язучылар да бар. Йөз туксан икенең егерме бере — Мари Республикасыннан. СССР Югары Суды Хәрби Коллегиясенең «Выездная сессия» рәисе корвоенюрист Матулевич, бригвоенюристлар Ждан, Колпаковның Мари Республикасына барып йөрергә вакытлары «тыгыз» була. Хөкемгә тартылганнарның зур күпчелеге, гаебен таныганы да, танымаганы да иң югары җәза — атылуга хөкем ителә һәм карар 1934 елның беренче декабрендә кабул ителгән закон нигезендә кичекмәстән үтәлә барган.

Әхмәтсафа Дәүләтъяровның «эш»ен суд биш минут чамасы «караган». Совет судында дөреслек тантана итәр дигән өмет кояшы шушы биш минутта мәңгелеккә сүнеп тә өлгергән...

Приговор

Именем Союза Советских Социалистических Республик

Выездная сессия

Военная коллегия Верховного Суда Союза ССР

В составе

Председатель корвоенюрист тов. Матулевича;

членов: бригадных военюристов тт. Ждан и Колпакова при секретаре воен. юриста 3-го ранга т. Козлова в закрытом судебном заседании в городе Казани

9 мая 1938 г. рассмотрел дело по обвинению Давлетъярова Ахмет-Сафа Мустафовича, 1905 г. р., бывшего председателя Совнаркома Тат. АССР, в преступлениях 58–7, 58–8 и 58–11 УК РСФСР.

Предварительным и судебным следствием установлено, что Давлетъяров А.М., член антисоветской пантюркистской национальной организации, действующей на территории Татарии в блоке с правотроцкистской террористической организацией, в 1936–1937 г.г. проводил вредительскую работу в Татгосиздате, в 1937 г., являясь переводчиком и соредактором перевода книги тов. Сталина «Вопросы ленинизма», извращал последнюю в контрреволюционном духе, проводил вербовку новых лиц в антисоветскую национальную организацию и, как участник организации, был осведомлен о ее террористической деятельности против руководителей ВКП(б) и советского правительства, чем совершил преступления, предусмотренные ст. 58–2–7–8 и 11 УК РСФСР.

Руководствуясь ст. 319 и 320 УК РСФСР, военная коллегия Верховного Суда СССР

приговорила

Давлетъярова Ахмет-Сафа Мустафовича к высшей мере наказания — расстрелу, с конфискацией лично ему принадлежащего имущества.

Приговор окончательный и на основании закона от 1 декабря 1934 г. немедленно привести в исполнение.

Түбәндәге белешмә Әхмәтсафа Дәүләтъяровның туганнары кулына озак еллар үткәч кенә килеп керә. Аның язмышы хакында уллары егерме елга якын бихәбәр булып яшиләр, әтиләре кайчан да булса алар янына исән-имин кайтып керер дигән өмет соңга кадәр ташламый. Бусы да тарих...

Справка

Приговор о расстреле Давлетъярова Ахмет-Сафа Мустафовича приведен в исполнение в гор. Казани 9 мая 1938 года. Акт о приведении приговора в исполнение хранится в особом архиве 1-го спецотдела НКВД СССР, том № 10, лист 492.

Нач. 12 от-я 1 спецотдела НКВД СССР лейтенант госбез. Кривицко.

...Һәр елның унтугызынчы октябрендә Казанның Архангел зиратына киләләр Марат белән Марлес Дәүләтъяровлар. «Сәяси репрессияләр корбаннарын искә алу көне» дип игълан ителгән көн бу. Зиратта корбаннар истәлегенә таш куелган. Ташка аларның сөекле әтиләре Дәүләтъяров Әхмәтсафа Мостафа улының исеме дә уеп язылган... 1905 елда туган, 1938 елда җәлладлар тарафыннан гомере киселгән әтиләре белән үткән һәр көнне хәтерләрендә яңартырга омтылалар. Алар истәлекләр белән яшиләр. Кызганыч, сабый чакта ук әти-әнисез калган Марат белән Марлесның хәтерләрендә күп нәрсәләр саклана алмаган шул. Сакланганнарының һәркайсысы изге, кадерле, күпме генә хәтердә яңартсалар да, аларның яктылыклары җуелмый, тәэсирләре кимеми. Әти-әни турында бит ул истәлекләр, үзләренең нурлы балачаклары турында...

Әй гомер, гомер... Агачларга сары иңгән. Яфраклар әкрен искән җилдә бөтерелә-бөтерелә аяк астына коелалар. Берәү, икәү, өчәү... һай, санап кына бетерерлекмени җил тарафыннан ирексезләп алып китеп, җир өстенә сибелгән бу яфракларны. Үләннәр сула, яфраклар коела... Табигатьтәге котылгысыз әйләнешнең көз фасылы өчен гадәти халәт бу. Агачларда әлегә коелмый калган яфраклар җилләрне үчекләп, лепер-лепер нидер сөйләшәләр, бер тынып калалар, кисәк шаулашып алалар — аларның аз гына, чак кына вакытлары бар бит әле, нигә яшәү рәхәтен татып калмаска ди! Ә аннары тагын яз җитәр, агачлар яшеллеккә күмелер, үләннәр күпереп үсеп чыгар. Табигать агышына Ходайдан башка беркем дә үзгәреш кертә алмый шул. Аяныч нәрсә бар: тарих кына кабатлана, диләр. Йөрәккә шом сала торган сүзләр бу.

Кешеләрнең язмышлары белән кешеләр үзләре «уйнарга» һәвәс. Югыйсә бер киткәч кайтмый кеше, мәңгелеккә китеп югала. Мәңгелекнең исә аерым шәхесләр, җан иярендә, яфрак-үләннәрдә эше юк. Аның үз табигате, үз холкы, ул кабатланганны яратмый, аның һәр мизгеле үзгә. Киткән кешеләр исәннәрнең генә күңелендә саклана. Кайберләрен көчләп оныттырырга тырышсалар да, кайчан да булса хәтер буйлап кайтып җитәләр, дөньяга аваз салалар: бу дөньядан без дә кичеп-үттек бит, без дә сезнең кебек үк якты өмет-хыяллар белән яшәдек, матур тормыш корырга азапландык,

безнең дә тарихта эзле буласы килде... Безне бер генә кеше булса да хәтерлиме дөньяда? Юкмы? Алайса, без тагын-тагын кайтып карарбыз, хәтерләрдә терелгәнче. Безнең кайтасы килә, үз язмышларыбыз турында сезгә сөйлисе килә. Гыйбрәт алсыннар дип, безнең ялгышларны кабатлый күрмәсеннәр дип искәртәсе килә яңа чор кешеләрен. Тыңлыйсыгыз килмиме? Вакытыгыз юкмы? Без дә сезнең кебек вакыт җиткерә алмый «тилмерә» идек шул, үткәннәр хакында ишетми калырга теләсәк... Без күргән-кичергәннәрдән сабак алырга бик кирәк тә бит, ай-һай, нык ышанып барасыз үзегезнең сукмакларыгыз буйлап. Яныгыздан нәүмизләнеп карап калган мәңгелек кануннарга әйләнеп тә карамыйсыз. Ни хәл итмәк кирәк, без дә шулай идек...

Марат белән Марлесның үткәннәрне, әтисе-әнисе белән бергә-бергә яшәгән бәхетле көннәрен бик тә кайтарасылары килә дә, юк шул, моңа адәм баласының кодрәте җитми. Кулларыннан килгән иң бөек эшне — әти-әнисенең хаксыз гаепләнгән булганын исбатлый алдылар алар.

...Әхмәтсафа Дәүләтъяровның атып үтерүгә хөкем ителгәнен һәм хөкем карарының 1938 елның тугызынчы маенда гамәлгә ашырылуын озак еллар үткәч, 1956 елда гына белә алдылар алар. Шушы ук елда аны гаепсез дип аклыйлар да...

Рабига апаның, Марат белән Марлес абыйларның Әхмәтсафа агадан соңгы язмышлары хакында, исән булсак, Ходай көч һәм зиһен бирсә, алда язармын әле дип ният итәм.

Ун елга сузылган эзләнүләрем нәтиҗәсе бу әсәр. Язган чакта башымда еш кына каршылыклы фикерләр дә кайнашып алдылар. Аңлармы мине укучы? Без тиз онытырга күнектерелгән халык бит. Хәтерсез халык — хәтәр халык, хәтерсез кавем — мескен кавем... «Ул елларны кат-кат искә төшерү ник кирәк?» — дип чәчрәп чыгучылар да булгалап тора.

Инануымча, язучы кулы кычытканга түгел, халкыбыз, аерым кешеләр язмышы кичергән гыйбрәтле хәлләр хакында язарга кирәк булганга яза. Бу аның намус эше, бурычы. Бар курыкканым, алдан әйткәнемчә, тарихның кабатланырга мөмкин булуы. Татарга кабатланган тарих югалган дәүләтчелеген дә, ирек кояшын да алып килмәс шул инде, бәла-казалар гына өеп китерер кебек. Шуларны истә тотып, тарихтан сабак алыйк дип язылган әсәр бу.

Яшьтән инкыйлаб өермәсе үзенә ияртеп киткән, шул чор идеяләре белән адарынып, «яңа тормыш төзибез, бар халыкны бәхетле тормышка чыгарабыз» дип, янып-ялкынланып йөргән Әхмәтсафа Дәүләтъяров, инкыйлаб үзе үк барлыкка китергән репрессия тегермәне ташлары астында калып уала, һәлак була. Мин геройның тормыш юлын сурәтләп чыгу максатын куймадым. Күпме язсаң да, кешенең тормышын

җентекләп тасвирлап бетереп булмый. Кеше күңеле — үзе бер дөнья. Дөньяны каләм белән түгел, хәтта акыл белән генә дә иңләп чыгып булмас кебек.

Максатым бер генә иде — мең еллар дәвамында табигый үсештә үзгәрә барган тормыш-яшәешне, тормышка ашырырдай тоелса да, әмма, нигездә, хыялый идеяләргә ышанып җимереп, аның урынына яңа эпоха, социализм төзергә, бик күпләрне бәхетле тормышка чыгарам дип, адарынып, ашкынып йөргән аерым бер кеше — татар егете язмышы аша мин шул чорның каршылыклы якларын, Әхмәтсафа ага белән бергә аралашкан бик күп күренекле шәхесләребез хакында тормышта алар ничек булган, шулай — нәкъ менә истәлекләрдә, архив материалларында теркәлеп калганча, артык бизәми-чукламый язарга җөрьәт иттем.

Бу әсәрем нахак гаепләр тагылып, газиз гомерләре кыелган барлык корбаннарның рухына дога булып ирешсен иде. Амин.

*Чаллы–Каргалы–Оренбур–Казан–Чаллы.*
*1999–2003*



## ЭЧТӘЛЕК

*Наис Гамбәр.* «Талантлы син, Кеше туганым!» (Кереш мәкалә.) . . . . . . . . . . 5

**Беренче китап**. Сакмар егете . . . . . . . . . . 22

**Икенче китап.** Өермә . . . . . . . . . . 202

**Өченче китап**. Ялган тәрәзәле йорт . . . . . . . . . . 392

Литературно-художественное издание

*Факил Сафин*

*(Сафин Факил Миннемухамитович)*

**Заблудившийся рассвет**

Роман-трилогия

(на татарском языке)

Редакторы *Р.Ә.Заһидуллина*
Рәссамы *М.Я.Разногорская*
Бизәлеш редакторы *Р.Г.Шәмсетдинов*
Техник редакторы һәм компьютерда биткә салучы *Н.Н.Мусина*
Корректорлары *Л.Ш.Шәфыйкова, Г.Г.Гарифуллина, Г.М.Хәбибуллина*

Нәшриятка 04184 нче номерлы лицензия
2001 елның 6 мартында бирелгән.

Оригинал-макеттан басарга кул куелды 26.11.2003.
Форматы $84 \times 108^{1}/_{32}$. Офсет кәгазе. «Peterburq» гарнитурасы.
Офсет басма. Шартлы басма табагы 27,72+фор.0,21.
Шартлы буяу-оттиск 28,98. Нәшер-хисап табагы 30,73+фор.0,36.
Тиражы 5000. Заказ Я-757.

Татарстан китап нәшрияты. 420111. Казан, Бауман ур., 19.
Татарское книжное издательство. 420111. Казань, ул.Баумана, 19.
**http://tatkniga.ru**
**e-mail: tki@tatkniga.ru**

«Идел-Пресс» нәшрият-полиграфия комплексы дәүләт унитар предприятиесе.
420066. Казан, Декабристлар ур., 2.